АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Институт языка, литературы и искусства
имени Г. Ибрагимова**

# ИСТОРИЯ ТАТАРСКОГО ЛИТЕРАТУРНОГО ЯЗЫКА (XIII – начало XX века)

II том

Морфология. Структурно-субстанциональные особенности
и функционально-стилистические возможности
грамматических категорий

*Письменные традиции, норма
и вариативность*

Казань
2017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
**Г. Ибраһимов исемендәге**
**Тел, әдәбият һәм сәнгать институты**

# ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ ТАРИХЫ (XIII гасыр – XX йөз башы)

II том

Морфология. Грамматик категорияләрнең
структур-субстанциональ үзенчәлеге
һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре.
*Язма традицияләр, норма*
*һәм вариантлылык*

Казан
2017

**УДК 811.512.145´0**
**ББК 81.2Тат-03**
**Т 23**

*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

«2014–2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында басыла

**Проект җитәкчесе** – филол. фән. докт., проф. **И.Б. Бәширова**

**Томның авторлары:**
филол. фән. докт., проф. **И.Б. Бәширова**, филол. фән. докт., проф. **Ф.Ш. Нуриева**,
филол. фән. канд., доц. **Э.Х. Кадыйрова,** филол. фән. канд., доц. **Р.Ф. Мирхәев**

**Фәнни редактор** – филол. фән. докт., проф. **Ф.М. Хисамова**

**Җаваплы редакторлар:**
филол. фән. канд. **Б.К. Миңнуллин**,
филол. фән. канд., доц. **Р.Ф. Мирхәев,**
филол. фән. канд., доц. **Г.Ф. Гайнуллина**

**Рецензентлар:**
филол. фән. докт., проф. **Ф.Й. Йосыпов,**
филол. фән. канд., доц. **А.Ф. Йосыпов**

**Т23 Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы)** / И.Б. Бәширова, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадыйрова, Р.Ф. Мирхәев; фәнни ред. Ф.М. Хисамова. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – II т.: Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. – 888 б.
ISBN 978-5-93091-248-7

Монография – Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында тормышка ашырыла торган «Татар әдәби теле тарихы» проектының икенче томы. Хезмәттә иске татар язма әдәби теленең XIII гасырдан XX гасыр башына кадәр морфология өлкәсендәге эзлекле үсеш-үзгәреше күзәтелә. Китап тел белгечләренә, аспирантларга, студентларга һәм татар әдәби теле тарихы белән кызыксынган киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

**УДК 811.512.145´0**
**ББК 81.2Тат-03**

**ISBN 978-5-93091-248-7**

© Авторлар коллективы, 2017;
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2017

## КЕРЕШ СҮЗ

Әдәби тел үзенең табигате һәм вазифасы белән катлаулы күренеш тәшкил итә. Аның лингвистик нигезе язма истәлекләрдә чагылыш тапкан традицияләр, нормалар һәм билгеле бер төбәккә хас булган җанлы сөйләмә формалар белән бәйләнеш-мөнәсәбәттә формалаша. Шул ук вакытта әдәби телнең табигатендә иҗтимагый тормышта бара торган төрле сәяси вакыйгалар, ягъни экстралингвистик факторлар да чагылыш таба. Шуңа бәйле рәвештә ул фәнни яктан төрле аспектлардан чыгып өйрәнелергә тиеш. Мәсәлән, гасырлар дәвамында кулланылышта булган иске татар әдәби телен: а) аерым бер чорга караган язма истәлекләрнең тел үзенчәлекләре, ә) әдәби телнең аерым бер жанр-стиленең теле, б) язма истәлекләрдә гомумтөрки традицияләрнең дәвам ителеше, в) аларда җанлы-сөйләмә формаларның кулланылыш үзенчәлекләре һ.б. юнәлешләрдә тикшерергә мөмкин.

Нинди генә аспекттан чыгып каралса да, әдәби тел, аның табигате һәм тарихы иң беренче чиратта лингвистикада кабул ителгән тәртиптә, ягъни телнең фонетика, морфология һәм лексика тармакларына нигезләнеп өйрәнелергә тиеш. Моңа кадәр күп санлы иске татар язма чыганаклары нәкъ менә шул планда тикшерелде.

Бүгенге көндә Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында тормышка ашырыла торган «Татар әдәби теле тарихы» проекты белән бәйле фәнни-тикшеренү эше дә әлеге тәртиптә алып барыла. Төп максатларның берсе булып әдәби тел үсешендә тарихи эзлеклелекне күрсәтү тора, һәм әлеге эзлеклелек әдәби телгә хас булган норма, норма вариантлылыгына нигезләнеп аңлатыла. Мәгълүм булганча, норма һәм норма вариантлылыгы, әдәби телнең табигатен һәм вазифасын барлыкка китерә торган традиция-дәвамчанлык, эшкәртелгәнлек, диалектлардан өстенлек кебек

төп билге-шартларның берсе булып тора, шул ук вакытта ул аларның барысын бергә оештырып тоту көченә ия. Гасырлар дәвамында эзлекле рәвештә яшәештә-хәрәкәттә булган иске татар әдәби теленең фонетика, морфология, лексика тармакларына хас булган язма традицияләрне, норма һәм норма вариантлылыгын, аларның төрле чорлардагы үсеш-үзгәрешен күзәтү хәзерге татар әдәби теле нормаларының да нинди шартларда, ничек итеп барлыкка килүен билгеләргә ярдәм итә.

Укучы игътибарына тәкъдим ителгән бу коллектив монография – өч томлык «Татар әдәби теле тарихы» хезмәтенең икенче томы. Хезмәттә XIII гасыр – XX гасыр башы иске татар теленең төрле жанр-стильләрендә (матур әдәбият, фәнни әдәбият, иҗтимагый публицистика, дини-дидактик әдәбият һ.б.) язылган текстларда файдаланыла торган тел берәмлекләре, хәзерге татар әдәби телендә кабул ителгән нигездә, морфологиянең грамматик категорияләренә мөнәсәбәттә, структур төзелеше-субстанциональ мәгънәсе ягыннан тикшерелә. Шул ук вакытта, язма текстларда аерым функциональ сөйләм тибын барлыкка китерү өчен махсус рәвештә сайланып алынган чара буларак кулланылулары игътибарга алынып, аларның функциональ-стилистик мөмкинлекләре анализлана, ягъни грамматик категорияләрнең (һәм форма, һәм мәгънәләренең) традиция-дәвамчанлыгы, әдәби норма, норма вариантлылыгы, функциональ-стилистик вариантлылыкка ия булу мәсьәләләре тикшерелә. Әлеге нигездә морфологик аспектта язма әдәби телне анализлауның принциплары тәгаенләнә.

Фәнни-тикшеренү эше татар тел белемендә кабул ителгән чорлар бүленешенә нигезләнеп алып барылды. Хезмәтнең кереш өлеше И.Б. Бәширова тарафыннан язылды, аерым чорларга караган язма чыганакларда чагылыш тапкан морфологик үзенчәлекләр Ф.Ш. Нуриева («Болгар дәүләте чоры Идел буе төрки язма әдәби теленең морфологик үзенчәлекләре», «Алтын Урда чоры Идел буе төрки-татар язма әдәби теленең морфологик үзенчәлекләре»), Э.Х. Кадыйрова («Казан ханлыгы чоры иске татар язма әдәби теленең морфологик үзенчәлекләре», «XVII–XVIII гасырларда иске татар язма әдәби теленең морфологик үзенчәлекләре»), И.Б. Бәширова («XIX–XX гасыр башында иске татар язма әдәби теленең морфологик үзенчәлекләре. Исем. Сыйфат. Рәвеш. Сан. Алмашлык. Затланышлы фигыльләр») һәм Р.Ф. Мирхәев («XIX–XX гасыр башында иске татар язма әдәби теленең морфологик үзенчәлекләре. Затланышсыз фигыль формалары») тарафыннан тикшерелде.

Хезмәт түбәндәге чыганакларга нигезләнеп язылды:

1. Болгар дәүләте чоры чыганаклары: «Кыйссаи Йосыф» (Кол Гали), «Ана вә угыл» дастаны.

2. Алтын Урда чоры чыганаклары: «Кыйссасел-әнбия» (Насреддин Рабгузи), «Нәһҗел-фәрадис» (Мәхмүд Болгари әс-Сараи), «Мәхәббәтнамә» (Харәзми), «Хөсрәү вә Ширин» (Котб) һ.б.

3. Казан ханлыгы чоры чыганаклары: Мөхәммәдъяр, Өмми Камал әсәрләре, «Мәҗмәгыль-кавагыйд» хезмәте һ.б.

4. XVII–XVIII гасыр чыганаклары: Мәүлә Колый, Габдессәлам, Габдерәхим Утыз-Имәни әсәрләре һ.б.

5. XIX гасыр – XX гасыр башы чыганаклары: Г. Кандалый, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки, Ә. Уразаев-Кормаши, М. Акъегет, З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Тукай әсәрләре һ.б.

Алга таба «Татар әдәби теле тарихы» проекты кысаларында иске татар язма чыганакларында чагылыш тапкан лексик-семантик категорияләргә караган нормаларның формалашу һәм үсеш-үзгәрешен өйрәнү күздә тотыла. Фәнни-тикшеренү эшенең нәтиҗәләре өченче томда яктыртылачак.

## КЕРЕШ

**Хәзерге татар тел белемендә грамматик категорияләрнең фәнни-теоретик яктан өйрәнелеше.** Укучыларга тәкъдим ителә торган «Татар әдәби теле тарихы»ның II томы, гарәп графикасы белән иске татар телендә язылган истәлекләрнең морфологиясен, ягъни сүз төркемнәрен тикшерүгә багышлана. Гасырлар буена эзлекле рәвештә дәвам итеп килгән классик иске татар телендә язылган әсәрләрдә, һәр сүз төркеменә хас булган грамматик мәгънә һәм грамматик формаларның ничек итеп файдаланылуын өйрәнүне дә, «Татар әдәби теле тарихы»ның I томын язу барышында, әдәби тел тарихын күзәтү өчен кулай дип саналган принцип нигезендә алып бару зарур дип табылды. Хезмәттә XIII гасырдан – XX гасыр башына кадәрге дәвердә иҗат ителгән, шәрехләнгән, күчереп язылган истәлекләрнең фонетик, график, орфографик үзенчәлекләре өйрәнелде. Биредә, беренче чиратта, гарәп һәм фарсы алынмаларының катгый рәвештә үз чыганак телендә язылуын истә тотып, төрки-татар сүзләрендә сузык һәм тартык авазларның гарәп графемалары ярдәмендә бирелеш үзенчәлекләрен тикшерү төп максат итеп куелды. Икенчедән, куелган максатка ирешү өчен, эш барышында бүгенге көндә татар авазларын белдерә торган кирилл хәрефләрен алгы планга чыгарып, һәр сузык һәм тартык авазның хәзерге әдәби телдәге асыл табигате, ягъни фонема яисә аллофон булуы, таралю-киңәюүе, ассимиляция-диссимиляция, рәт һәм ирен гармониясенең саклану-сакланмавы, ясалу урыннары һ.б. игътибарга алынды. Әлегә кадәр әдәби истәлекләр өйрәнелеп язылган хезмәтләрдән күренгәнчә, анализны гарәп графемасы белән башлаганда, асылда, шул графеманың мөмкинлеге, ягъни аның ничә татар авазына билге була алуы ачыклана, әмма төрки-татар әдәби телендә графика һәм орфографиягә караган язма традициянең ничек дәвам ителешен

күзәтеп булмавы аңлашылды. Кирилл хәрефе белән белдерелә торган татар авазының гарәп графемасы ярдәмендә ничек итеп күрсәтелүен анализлау, истәлекләрнең графо-орфографик тәртибен билгеләгәндә төп принцип итеп алынды. Төрки-татар телендәге сузык һәм тартык авазларның сүз башында, уртасында һәм ахырында бирелү үзенчәлекләре өйрәнелде. Тикшерүне әлеге нигездә алып барганда гына, иске татар телендә язма традиция, норманың эзлекле рәвештә дәвам ителүен, аның вариантларының ни өчен барлыкка килүен билгеләргә мөмкин булуы, ягъни әдәби тел тарихын өйрәнүнең дөрес юнәлештә баруы аңлашылды. Шуңа күрә бу ысул, ягъни тел берәмлегенең хәзерге хәлдәге табигый-субстанциональ үзенчәлеген төгәл аңлаганнан соң гына, аның билгеле бер текстта ничек итеп файдаланылуын күзәтү иске татар телендә язылган текстны тикшерүнең төп принцибы булып ассызыкланды.

Шул ук вакытта, «...әдәби тел тарихын өйрәнү гомумтел элементларын билгеләү һәм тикшерүгә, шулай ук тел системасының гомуми грамматик һәм лексик-семантик категорияләрен аңлауга нигезләнүен» [Виноградов, 1978, с. 278] истә тотып, һәр язма истәлек телен өйрәнүнең нәтиҗәләре әдәби телнең кайсы стилендә язуына карап, тел берәмлекләрен сайлап алып кулланырлык байлык-запаска ия булуы ачык күренде. Авторларның теге яки бу тел берәмлеген ни өчен сайлап алуына, язма традициянең ни дәрәҗәдә саклану-сакланмавына һәм сөйләм теле, диалектлардагы сүз, сүзформаларның ничек әдәбиләштерелүенә игътибар итәргә, тел берәмлекләренең язма чыганакларда файдаланылу үзенчәлекләрен билгеләргә, әлеге нигездә авторның язганнарына карата мөнәсәбәтен күрсәтергә мөмкин булуы ачылды. Бер уңайдан, язма әдәби тел дигән күренешнең, гомум сөйләмә телдән аермалы буларак, асыл табигатенә һәм вазифасына хас булган төп үзенчәлекләренең [Тенишев, 1988, с.72–73] төрки-татар язма истәлекләрендә чагылыш табуы күзәтелә барды [Татар әдәби..., 2015, б. 206–232].

«Татар әдәби теле тарихы...»ның II нче – морфологиягә багышланган томын язганда да, текст эчтәлегендә, күп кырлы вазифа үти ала торган тел берәмлегенең функциональ мөмкинлеген күзаллау өчен, аның, язма сөйләмгә (текстка) килеп кергәнче үк, үзенә генә хас булган табигатен, ягъни структур-субстанциональ төзелешенең асылын төгәл белергә кирәк булуы аңлашылды.

Әлеге максатка ирешү юнәлешендә, беренчедән, грамматик категория, грамматик мәгънә һәм грамматик форма кебек төшенчәләрнең

хәзерге вакытта татар теле белемендә ничек итеп аңлатылуы; икенчедән, һәр сүз төркеме тикшерелгәндә, теоретик фикерләрнең гамәли яктан ничек файдаланылуы өйрәнелде. Аңлашылганча, тикшерү эшенең тагын да катлаулануы күренде. Бу очракта, лексик-семантик яктан төрле булган сүзләрнең, гомумкатегориаль грамматик мәгънәгә бәйле рәвештә лексик-грамматик яктан гомумиләшүе нигезендә барлыкка килә торган сүз төркемнәренең, һәм һәр сүз төркеменең үзенә хас булган грамматик мәгънә һәм грамматик форма берлегеннән оешкан катлаулы табигатен аңлап эш итү максаты куелды. Аңлашылганча, тикшерү эшенең тагын да катлаулануы күренде.

Телнең грамматик төзелешен барлыкка китерә торган морфемика, морфонология, сүзьясалышы, морфология һәм синтаксис тармаклары тикшерелеп язылган хезмәтләрдән күренгәнчә, грамматик категория дигән күренешнең, хәзерге татар теле белемендә, берсе икенчесенә бәйле булган ике аспектта: а) гомуми теоретик нигездә күзаллануы һәм ә) аерым сүз төркемнәренә хас булган үзенчәлек буларак өйрәнелүе мәгълүм.

Гомуми теоретик планда күзаллана дигәндә, татар теленең рус һәм татар телләрендә дөнья күргән академик грамматикасында төп грамматик төшенчәләр турында бирелгән мәгълүмат күз алдында тотыла [Татарская грамматика, 1993, т. I, с. 130–141; Татар грамматикасы, 1998, т. I, б. 152–161]. Әлеге хезмәттә «...иң элек аның гомуми төшенчәләрен җыеп тәртипле итеп бирү сорала» диелә һәм алар түбәндәгечә аңлатыла: «Телнең грамматик төзелеше – ул сүзнең, сүз төркемнәренең, җөмләләрнең һәм сөйләмнең (текстның) структур төзелеш системасы. Грамматика фәне – ул сүзнең, сүз төркемнәренең, җөмләнең һәм сөйләмнең структур төзелеш системасы турындагы өйрәтмә» [Татар грамматикасы, 1998, т. I, б. 152].

Алга таба грамматик төзелешнең тел һәм сөйләмгә мөнәсәбәтле рәвештә тикшерелергә тиешлеге ассызыклана: «Сөйләм теленең табигый халәте, тел, аралашу коралы буларак, сөйләмнән барлыкка килгән. Сөйләм кешеләр арасында аралашу ихтыяҗыннан туа, ә аралашу бер-береңә ниндидер яңа фикер хәбәр итү аркылы бара. Аралашу өчен, сөйләүче кирәкле төшенчәләрне белдерүче сүзләрдән (я бер сүздән) җөмлә оештыра, җөмләләрдән сөйләм (текст) оеша» [Татар грамматикасы, 1998, т. I, б.153]. Сөйләмнең барлыкка килүе, асылда, лексик һәм грамматик мәгънәләр нигезендә баруына игътибар ителә: «Сөйләмдә кулланылганда, сүзләр үзләренең лексик мәгънәләре белән

бергә, грамматик мәгънәләр дә алалар. Бу төр мәгънәләр, сөйләгәндә, сүзләр арасында, сөйләүче белән чынбарлык (тыңлаучы, сөйләм, аның эчтәлеге, сөйләм вазгыяте – обстановкасы) арасында урнашкан мөнәсәбәтләргә туры киләләр. Грамматик мәгънәләрне белдерүче махсус грамматик чаралар була... . Грамматика фәне менә шул сөйләм оештыручы сүзләр, аларның грамматик мәгънәләре һәм грамматик чаралар белән эш итә, шуларның, хәрәкәткә килеп, җөмлә һәм сөйләм төзүләрен тикшерә. Грамматика фәне телне һәм сөйләмне синхроник планда гына, ягъни хәзер ничек булса, шул хәлендә алып кына өйрәнеп калмый, аны диахроник планда, ягъни электән хәзергә кадәр ничек үзгәреп, үсеп килү планында да өйрәнә» [Татар грамматикасы, 1998, т. I, б. 153].

Алга таба грамматик төзелешне барлыкка китерә торган морфемика, морфонология, сүзьясалышы, морфология һәм синтаксис бүлекләренең һәрберсенең үзләренә хас булган дә өйрәнү объектлары барлана, аларның үзара мөнәсәбәте күрсәтелә: «...Сүзләрнең сөйләмдә кулланылгандагы структур төзелешен, төрле төркемнәргә туплануын өйрәнү – морфологиянең объекты санала» [Татар грамматикасы, 1998, т. I, б. 154]. Сүзләрнең ничек итеп аерым төркемнәргә туплануы, грамматик күренеш һәм грамматик категория дигән махсус терминнар ярдәмендә аңлатыла: «...Грамматик күренешнең тышкы яңгырашы (формасы) һәм эчке мәгънәсе (эчтәлеге) була. Грамматикада эчтәлек – грамматик мәгънә дип, эчтәлекне белдерүче тел чаралары грамматик форма дип аталалар. Грамматик күренеш грамматик мәгънәнең һәм грамматик форманың берлегеннән тора, башкача әйткәндә, грамматик күренеш – грамматик мәгънәнең үзенә генә хас грамматик форма белән берелүе дигән сүз. Грамматик күренеш күп кенә очракларында грамматик категориягә тиң була» [Татар грамматикасы, 1998, т. I, б. 154]. Грамматик категория түбәндәгечә аңлатыла: «Грамматика фәнендә категория ике мәгънәдә йөри: 1) төркем, 2) грамматик күренеш. Грамматик категория – ул бер төрлерәк грамматик мәгънәләр белән берләштерелгән грамматик күренешләр төркеме, системасы. Мәсәлән, морфологиядә иң гомуми грамматик категория – сүз төркемнәре категориясе, ул аерым сүз төркемнәре җыелмасыннан, системасыннан тора» [Татар грамматикасы, 1998, т. I, б. 155].

Сүз төркемнәре категориясенә карата аерым сүз төркеме (исем, сыйфат, сан һ.б.) грамматик күренеш дип карала. Сүз төркемнәре категориясенә карата грамматик күренеш булган исем аның эчендә

карала торган килешләргә, тартымга, модальлеккә карата категория була һәм исем категориясе дип атала. Исем категориясенә карата грамматик күренеш булган килешләр аерым килешкә карата шулай ук категория булып санала һәм килеш категориясе дип атала. Килеш категориясенә карата нинди дә булса бер килеш (мәсәлән, чыгыш килеше) грамматик күренеш булып исәпләнә...» [Татар грамматикасы, 1998, т. I, б. 155]. Аңлашылганча, югарыдан түбәнгә таба грамматик категорияләр иерархиясе төзелә һәм аны башка мисалларда да күрсәтергә мөмкин дип санала.

«Гомуми тел белеме» курсында да грамматик категориянең грамматик мәгънә һәм аны формалаштыра торган грамматик чаралары берлеге дип аңлатуның объектив-дөреслеге раслана: телнең грамматик механизмының төп берәмлеге булган грамматик категория дигәндә, телдә реаль яши торган билгеле бер грамматик мәгънәләр белән, шул мәгънәне белдерә ала торган формаль күрсәткечләренең берлеге истә тотыла.

Шуның белән бергә, бу хезмәттә грамматик категорияләрнең барлыкка килүе, грамматик форма һәм грамматик мәгънә мәсьәләсе татар теле белеменә караганда башкачарак, ягъни сүзмәгънә, сүзформа һәм сүзтезмәләрнең гомумкатегориаль нигездә гомумиләшүе дип аерылып карала. Грамматик категория дигән күренеш дүрт төрле нигезгә утыртылып аңлатыла: 1) предметлык, предметның билгесен белдерү, процесслык, процессның билгесен белдерү, зат һәм предметның санын белдерү, яисә аларны алмаштыра алу кебек гомумкатегориаль грамматик мәгънәләр нигезендә төрле лексик-семантик төркемдәге сүзләр үзара берләшеп, исем, сыйфат, фигыль, рәвеш, сан, алмашлык кебек мөстәкыль сүз төркемнәре дигән I тип грамматик категория барлыкка китерәләр; 2) сөйләм барышында сүзләрнең үзара мәгънәви бәйләнешен тәэмин итә торган, һәр төркемнең үзенә хас булган грамматик формалары аерылып чыга: исем сүз төркемендә сан, тартым, килеш; фигыль сүз төркемендә барлык-юклык, зат-сан, наклонение, заман, дәрәҗә-ысул, юнәлеш; сыйфат сүз төркемендә зат һәм предметларның саф билгесен (кыяфәтен, характерын, төсен, тәмен, исен һ.б.) белдерә торган асыл һәм предметның башка предметлар белән төрле мөнәсәбәтләре нигезендә (вакыт, урын һ.б.) килеп чыккан билгесен белдерә торган нисби сыйфатлар; рәвеш сүз төркемендә эш-хәлнең саф билгесен (сыйфатлау, охшату-чагыштыру, күләм-чама) һәм эшхәл белән бәйле төрле хәлләрне (урын, вакыт, сәбәп, максат һ.б.) тәгъ-

бир итә торган билге һәм хәл рәвешләре нигезендә II тип грамматик категория хасил була. Әлеге ике грамматик категориянең берлеге һәм системасы нигезендә телнең морфология дип өйрәнелә торган тармагы барлыкка килә.

Алга таба сүзләрнең җөмләдәге урынына карап җөмлә кисәкләре дигән III тип, һәм аларның үзара бәйләнешеннән барлыкка килә торган сүзтезмәләре дигән IV тип грамматик категория формалаша. Бер төркем сүзләрнең җөмләдәге урынына карап аерымлана торган җөмлә кисәкләре һәм аларның бәйләнешеннән хасил булган сүзтезмәләрнең системасы нигезендә телнең синтаксис тармагы хасил була [Березин, Головин, 1979, с. 180–183].

Грамматик категорияне болай итеп аңлатуны нигез итеп алу, язма истәлекне тикшерү өчен уңайлырак булуы күренә, әмма бу очракта фикерне киңәйтеп бирү сорала. Димәк, грамматик категория – ул грамматик мәгънә нигезендә гомумиләшү нәтиҗәсе. Грамматик мәгънә нигезендә гомумиләшү дигәндә, беренче чиратта, әлеге мәгънәне белдерү өчен бер төркем сүзләрнең берләшүе кирәк.

Бу очракта бер төркем сүз дигән төшенчәне без ничек аңларга тиеш? Телнең универсаль берәмлеге булган сүзләрне төрле нигездә төркемләргә мөмкин: а) сүзләрнең нинди предметны атаһына карап барлыкка килә торган күп сандыгы төрле тематик төркемнәр (уку әсбаплары, савыт-саба, мебель һ.б.); ә) һәр аерым сүзнең нинди мәгънә белдерүенә һәм аның ничек итеп кулланылуына карап барлыкка килә торган лексик-семантик төркемнәр (мөстәкыйль һәм ярдәмче мәгънәле, ялгызлык һәм күмәклек, конкрет һәм абстракт мәгънәле һ.б.), сүз һәм мәгънә мөнәсәбәтендә оеша торган микросистемалар (полисемия, синонимнар, омонимнар, антонимнар һ.б.). Һәр аерым сүзнең бу мөмкинлеге сүзлектә теркәлә, ягъни тик торган халәтендә аңлатыла ала.

Ләкин аралашу барышында, бер кеше икенчесенә ниндидер фикер әйтә башлаганда, сүзләр аерым-аерым кулланыла алмый, алар үзара мөнәсәбәткә керергә тиеш була. Теләсә кайсы телдә, шул исәптән татар телендә дә, сүзләрнең үзара бәйләнеше шул телгә хас булган грамматик төзелеше нигезендә бара. Бу очракта төрле тематик һәм лексик-семантик төркемнәр булып, индивидуаль яши ала торган сүзләр, һәр сүз төркеменең категориаль лексик-грамматик мәгънәсе таләп иткән нигездә, үзара берләшергә тиеш була. «Гомуми тел белеме»ндә аңлатылганча, менә шундый төркем сүзләрнең барысын бергә гомумиләштереп тота торган грамматик мәгънә I тип грамматик

категориянең нигезен тәшкил итә. Әлеге нигездә мәгълүм сүз төркемнәре барлыкка килә һәм сөйләм оеша, ягъни бер сүз икенчесе белән бәйләнеш-мөнәсәбәттә файдаланыла башлаганда, алар ничек итеп (нинди чаралар белән), нинди грамматик мәгънә белдерә алуларына карап аерымлана.

Бу очракта, сүз төркеме дигәндә, сүзләрнең грамматик типта гомумиләштерелгән лексик-грамматик берлеге истә тотыла: «Части речи – это грамматически обобщенные классы слов, безразличные к лексическим их значениям, что не исключает, впрочем, взаимодействия между лексикой и грамматикой и известного давления лексики на грамматику...» [Березин, Головин, 1979, с.182–183].

Шулай итеп, лексик берәмлекләр грамматик мәгънә нигезендә, үзләренең лексик-семантик төрләрен һәм мөмкинлекләрен саклаган хәлдә, гомумиләшү сәләтенә ия. Бу үзенчәлек һәр сүз төркеменең үзенә хас булган табигате һәм вазифасында (категориаль мәгънәсендә) чагылыш таба. Исем сүз төркемендә, мәсәлән, ялгызлык, күмәклек, конкрет, абстракт, җыйма, матдә мәгънәле, ягъни лексик-семантик яктан төрле булган сүзләр, предметлык төшенчәсен яшәтү өчен гомумиләшә. Башка сүз төркемнәре дә һәрберсе үзенә хас булган уртак категориаль мәгънәгә тупланган лексик-грамматик ясылыкта хәрәкәт итә.

Уртак категориаль мәгънә сүз төркемнәренә хас булган грамматик мәгънәләр һәм формалар белән бергә карала. Әлеге формаларның гомумиләшүе II тип грамматик категория дип аерымланып бирелә. II тип грамматик категория дигәндә, сүз төркемнәренең һәрбересенең үзенә хас булган грамматик мәгънә нигезендә гомумиләшкән һәм шул мәгънәне белдерә торган чаралары булган сүзформалар классының категориясе истә тотыла. Исемнәрдә ул сан, килеш, тартым категорияләре; фигыльләрдә темпоральлек-заман, модальлек-наклонение категориясе, персональлек-зат категорияләре һ.б. I һәм II тип грамматик категорияләрнең берлеге телнең морфологик төзелешен барлыкка китерә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, иске татар әдәби телендә грамматик (морфологик) категорияләрнең кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнгәндә, югарыда әйтелгәннәрне күз алдында тотып, а) мәсьәләнең хәзерге татар тел белемендә һәм иске татар телендә язылган истәлекләрне өйрәнүчеләр тарафыннан ничек итеп тикшерелүен ачыклау, ә) грамматик категорияләрнең тел күренеше һәм сөйләм күренеше буларак кулланылышының аермасын аңлатып бирү сорала.

**Грамматик категорияләрнең гамәли яктан өйрәнелүе.** Аерым сүз төркемнәренә хас үзенчәлек буларак тикшерелгәндә, теоретик нигез ни дәрәҗәдә файдаланыла дигән сорауга җавап бирү өчен, телнең грамматик механизмының төп берәмлеге булып санала торган грамматик категория мәсьәләсенең хәзерге татар теле морфологиясе өлкәсенә караган хезмәтләрдә, ни дәрәҗәдә объектив һәм фәнни дәрәҗәдә аңлатылуын ачыклау сорала.

Академик басма буларак дөнья күргән татар грамматикасының морфологиягә багышланган II томында грамматик гомумиләштерү һәм грамматик категория дигән күренеш, кабул ителгән хосусый терминнары белән төгәл итеп билгеләнеп җитмәсә дә, теоретик нигез, асылда, истә тотыла дип әйтергә мөмкин. Мәсәлән, «Исем предметлыкны белдерә торган сүз төркеме. Бу – аның лексик-грамматик мәгънәсе», – дигән мәгълүмат бирелә, аерым тематик һәм семантик төркемгә караган лексик берәмлекләр санала һәм «...кыскасы, исем сүз төркемендә предметлаштырылып бирелгән теләсә нинди төшенчәне очратырга була», – дигән нәтиҗә ясала [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 25]. Терминнарны төгәлрәк файдаланганда: «Предметлык дип атала торган гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә лексик-грамматик яктан гомумиләшеп барлыкка килә торган сүз төркеме исем дип атала» яки «теләсә нинди төшенчәне очратырга була» дип түгел, «...төшенчәне атый торган сүзләрне» дип тәгаенләү сорала. «Исемнең семантик төркемчәләре» урынында, «исем сүз төркеменә хас булган предметлык мәгънәсе нигезендә лексик-семантик яктан төрле булган сүзләр туплана» дип белдерү, бу сүз төркеменә хас булган грамматик гомумиләштерүне тулырак аңлатачак.

Башка сүз төркемнәренә билгеләмә бирелгәндә дә, өстәмә рәвештә терминологик яктан конкретлаштыру сорала. Мәсәлән, «Сыйфат предметның киң мәгънәсендә процессуаль булмаган статик билгесен белдерә», – дип әйтелә һәм «предметның конкрет нинди мәгънәсен белдерүләренә карап, сыйфатлар түбәндәге лексик-семантик төркемнәргә бүленәләр» дип, әлеге төркемнәр санала. Аннан соң «Сыйфат төркемчәләре» исеме астында: «Лексик-грамматик үзенчәлекләреннән чыгып, сыйфатларны асыл һәм нисби сыйфатлар дип ике төркемгә бүлеп өйрәнәләр. Асыл сыйфатлар предметның саф билгеләрен белдерәләр» дип, лексик-семантик дип бүленгән төркемнәрнең кайберләре лексик-грамматик дип яңадан кабатлана: яшел, зәңгәр, түгәрәк, юаш, усал һ.б. Шулай итеп, предметларның саф билгесен белдерә торган

сүзләр лексик-семантик һәм лексик-грамматик яктан абсолют тәңгәл буларак аңлашыла [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 65–68]. Биредә сыйфат сүз төркеме дигән күренешне теоретик планда билгеләнгән терминнары белән аңлату сорала: «Предмет-әйберләрнең билгесе дигән гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә лексик-грамматик яктан гомумиләшеп барлыкка килә торган сүз төркеме сыйфат дип атала». Яисә: «Грамматик бәйләнеш-мөнәсәбәткә килеп кергәнче үк, үзенең мәгънәсе белән яшәештә булып, предмет-әйберләрнең билгесе дигән гомумкатегориаль түбә астына берләшә ала торган асыл сыйфатларны лексик-семантик төркемнәргә бүлеп карарга мөмкин».

Лексик мәгънәгә тагын грамматик төзелеш нигезендә аңлашыла торган мәгънә дә өстәлсә, боларны инде лексик-грамматик мәгънә дип аңлатырга тиеш булабыз. Мәсәлән, нинди сүзләр белән бәйләнүенә карап, бер үк сыйфат дәрәҗәсенең төрле мәгънә белдерә алуын, яисә лексик-семантик яктан предметның саф билгесен аңлата торган сүзләрнең тагын процессның билгесен дә белдерү өчен файдаланылуын, нисби дип бирелә торган сыйфатларның билге белән бергә төрле мөнәсәбәтләрне дә белдерә алуын һ.б.ны сыйфат сүз төркеменә берләшә торган сүзләрнең грамматик төзелеш таләп иткән бәйләнештә, сөйләм барышында үзенең төрле функциональ вазифалары белән кулланыла алу мөмкинлеге дип аңлатырга кирәк була.

Фигыль сүз төркеме хезмәттә, төрле авторларның һәрьяклап җентекләп тикшерүләре нәтиҗәсе буларак урын ала. Бу очракта да мәсьәләне башка сүз төркемнәре аңлатыла торган тәртиптә, ягъни: «Процессуальлек-хәрәкәт дип атала торган, ягъни предметның эшен-хәлен процесс рәвешендә белдерү дигән гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә лексик-грамматик яктан гомумиләшеп барлыкка килә торган сүз төркеме фигыль дип атала», – дип әйтергә тиеш булабыз.

Фигыль сүз төркеменә караган сүзләрнең төрле тематик һәм семантик төркемчәләре турында томда түбәндәге мәгълүмат бирелә: «Фигыль лексикасын мәгънәсе буенча төркемләү – шактый катлаулы эш, чөнки фигыльнең мәгънәсе үтә гомуми, үтә киң, һәм аның нигезендә объектлар арасындагы мөнәсәбәт ята. Шулай булуга карамастан, фигыльләр сүз буларак өйрәнелергә тиеш, чөнки шунсыз фигыльдәге категорияләрнең мәгънәсен һәм функциясен бөтен тулылыгы һәм тирәнлеге белән аңлап булмый» [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 100]. Фигыль сүз төркеменә берләшә торган сүзләр, «...төп мәгънәләреннән чыгып, ике зур төркемгә – эш-гамәл һәм хәл-торыш

фигыльләренә, ... өченче төркем итеп кешенең тормышында, бөтен эшчәнлегендә зур урын тоткан мөнәсәбәтләрне белдерүче фигыльләр төркеме аерылды» [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 103]. Алга таба әлеге төркемнәргә караган төркемчәләр санала. Аерым сүз белән белдерелә торган эш-гамәл һәм хәл-торыш төркеменә берләшә торган төркемчәләрдән үзгә буларак, мөнәсәбәт фигыльләре «кем яки нәрсә арасында мөнәсәбәт булуын белдерәләр. Мөнәсәбәт ситуациясе кимендә ике зат яки предмет арасында урнаша. Бу төркемгә караган фигыльләр башка төркемнәргә дә карый ала» [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 107]. Шулай итеп, фигыль сүз төркеменә берләшә торган сүзләр дигәндә, башка сүз төркемнәреннән аермалы буларак, аерым сүз булып белдерелә торган төшенчәләрнең атамасы белән бергә, башкаларда лексик-грамматик бәйләнеш дип аңлатыла торган мөнәсәбәтләрнең атамасы да лексик-семантик төркемчә буларак кабул ителә. Бу хәл фигыль сүз төркемнең табигатенә хас булган катлаулылыкның бер чагылышы санала.

Әлеге сүз төркеменең табигый яшәешен тәэмин итүдә мөһим роль уйнаган II тип грамматик категория санала торган гомумиләшкән сүзформаларының да катлаулы булуы мәгълүм: «Фигыль – предметның эшен, хәлен процесс рәвешендә белдерә торган һәм барлык-юклык, юнәлеш, дәрәҗә, наклонение, заман, зат-сан белән төрләнә торган сүз төркеме» [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 115]. Алга таба төрләнешне барлыкка китерә торган әлеге типлар үзләренә хас булган категориаль грамматик мәгънәсе һәм шул мәгънәне белдерә торган формасы белән бергә гомумиләштерелеп, категория буларак тикшерелә.

Хезмәттә рәвеш сүз төркеме түбәндәгечә аңлатыла: «Рәвеш – эш, хәл, билгеләрнең, сирәгрәк предмет һәм затларның процесска бәйле булмаган билгеләрен белдерүче сүз төркеме» [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 318]. Бу билгеләмәне хата дип әйтеп булмый, әмма аңа ачыклык кертү сорала сорала: «Эш, хәл, билгеләрнең, предмет һәм затларның процесска бәйле булмаган билгесе дигән гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә лексик-грамматик яктан гомумиләшеп барлыкка килә торган сүз төркеме рәвеш дип атала».

Рәвеш сүз төркеме аңлатыла башлаганда ук «лексик-грамматик мәгънәләре белән, башка телләрдәге кебек үк, сыйфатларга якын торалар», – дип белдерелә. Грамматик бәйләнеш-мөнәсәбәткә килеп кергәнче үк үзенең мәгънәсе белән яшәештә булып, эш-хәл, әйберләрнең,

билгеләрнең, предмет һәм затларның процесска бәйле булмаган билгесе дигән гомумкатегориаль түбә астына берләшә ала торган рәвешләрнең лексик-семантик төркемнәренең булу-булмавы хакында мәгълүмат бирелми. Рәвеш төркемчәләре дигәндә, аларның лексик-грамматик мәгънәләре буенча төркемләнүе истә тотылып, билге рәвешләре һәм эш-хәл рәвешләре аерып чыгарыла [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 318–321].

Әлеге юнәлештә сан һәм алмашлык сүз төркемнәрен дә, үзләренә хас булган гомумкатегориаль грамматик категорияләре нигезендә лексик-грамматик яктан берләшеп барлыкка килә торган төркемнәр икәнлегенә басым ясап тасвирлау сорала.

Һәрхәлдә, телдә реаль яши торган грамматик мәгънәнең үзенә кирәкле чаралары белән белдерелүеннән барлыкка килә торган грамматик категория һәм әлеге нигездә формалашкан сүз төркемнәре мәсьәләсе татар теле белемендә академик басма буларак тәкъдим ителә торган әлеге хезмәттә һәм нәзари (теоретик), һәм гамәли (практик) яктан эшкәртелеп укучыларга ирештерелгән дип әйтә алабыз, аерым очракларда терминнарны конкретлаштырырга кирәк булуы аңлашыла.

**Татар теле белемендә грамматик категорияләрнең диахроник планда өйрәнелеше**. Татар теленең академик грамматикасында, рәвештән кала, барлык сүз төркемнәренең билгеле бер дәрәҗәдә тарихи-диахроник планда өйрәнелеше дә тәкъдим ителә, ягъни грамматик категорияләргә хас булган структур төзелешнең тарихи планда ничек итеп тикшерелүе ачыклана. Грамматик категорияләрнең синхроник халәте, билгеле бер дәрәҗәдә, аларның диахроник-тарихи планда өйрәнелешенә нигезләнеп аңлатыла.

Шуның белән бергә, әлеге мәсьәләнең төрле максатны күздә тотып язылган хезмәтләрдә төрлечә тикшерелүе мәгълүм булганга, хәзерге тел белеменә мөнәсәбәттә, аларның ничек аңлатылуын белү сорала. Бу юнәлештә татар теле, шул исәптән аның грамматик төзелеше өйрәнелеп язылган беренче дәреслекләрне кем өчен, нинди максат белән язылуына карап, а) русларга татар татар телен өйрәтү өчен языла торган кулланмалар, ә) татар телен фәнни яктан өйрәнә башлаган хезмәтләр дип ике төркемгә бүлеп карарга кирәклекнең мөһим булуы игътибарны җәлеп итә [Хангилдин, 1965, б. 281–293].

А.Н. Кононовның «История изучения тюркских языков в России» (1982) исемле хезмәтендә, барлык төрки телләр белән рәттән, кыпчак телләре төркеменең кыпчак-болгар төркемчәсенә карый тор-

ган татар теленең дә өйрәнелеше күзәтелә. Автор татар теленең, төрки телләрдән беренче булып, XVIII гасыр уртасында русларга укыту өчен программасы язылуын, мөмкин булган дәрәҗәдә лексик байлыгы барланып, С. Хәлфин тарафыннан сүзлеге төзелүен искә алгач, грамматик яктан өйрәнелешен анализлауга күчә. Бу юнәлештә М.З. Зәкиевнең мәкаләләре, М.З. Закированың «Исторический обзор грамматик татарского языка» исемле кандидатлык диссертациясе (1951), Я.С. Әхмәтгалиеваның китабы (1979), әдәбиятчы һәм тарихчыларның хезмәтләре файдаланыла, русларга татар телен өйрәтү өчен язылган түбәндәге дәреслек-кулланмаларга, сүзлекләргә игътибар ителә: «Грамматика татарского языка...» (И. Гиганов, 1801), «Букварь татарского и арабского письма...» (Н.Б. Атнометов, 1802), «Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения...» (И. Хальфин, 1809), «Краткая татарская грамматика...» (1814, 1824, 1860), «Словарь татарского языка...» (А.А. Троянский, 1833), «Татарская грамматика», «Татарская хрестоматия» (М.И. Иванов, 1842), «Практическое руководство к изучению татарского языка» (М.-Г. Махмудов, 1857), «Татарская хрестоматия», «Словарь к татарской хрестоматии» (С.Б. Кукляшев, 1859), «Нәхү китабы» (К. Насыйри, 1860), «Краткая татарская грамматика...» (1860), «Краткая учебная грамматика татарского языка» (Х. Фәезханов, 1862), «Белек» (В.В. Радлов, 1872), «Татарско-русский словарь» (К. Насыйри, 1875), «Полный русско-татарский словарь...» (К. Насыйри, 1892, 1906), «Ләһҗә-и-татари» (К. Насыйри, т. I, 1895; т. II, 1896], «Әнмүзәҗ» (К. Насыйри, 1895), «Материалы к изучению казанско-татарского наречия» (Н.Ф. Катанов, 1899). Аңлашылганча бу исемлектә татар телен фән буларак тикшереп язылган кайбер хезмәтләрнең дә теркәлүе күренә, аларның һәрберсенә карата әйтелгән фикерләргә нигезләнелеп, әһәмиятләре ассызыклана. Шуның белән бергә төрле авторлар тарафыннан төзелгән кулланмалар да санала [Кононов, 1982, с. 258–270].

М.З. Зәкиев, татар теле академик грамматикасының (II т.) «Кереш» өлешендә, русларга татар телен өйрәтү максатын күздә тотып язылган бу хезмәтләр белән «төрки-татар морфология фәненә нигез салынган», «...татар теленнән рус теле категорияләренә туры килә торган формалар эзләгәннәр. Шул формаларны рус телен тикшерүдән килеп чыккан морфологик калыпларга сала барганнар. Бер яктан, моның әһәмияте бик зур булган: рус лингвистикасындагы алдынгы карашлар татар грамматика фәненә турыдан-туры керә барган, һәм ул татар

телен башлап тикшерүдә бик якты маяк хезмәтен үтәгән» дип, аларның хәзерге тел белеме өчен дә игътибарга лаек булуын ассызыклый. Шунда ук әлеге эшчәнлекнең әһәмиятле ягы белән бергә, тискәре яклары да күрсәтелә: «...Татар теле морфологиясенең бары рус теле категорияләренә туры килгән өлешләре генә ныклап өйрәнелеп, рус теле үзенчәлекләренә тәңгәл килмәгәннәре читтә кала торган булганнар. Җитмәсә, рус теленең берәр үзенчәлеге татар телендә табылмаса, аны татар теленең һәм халкының «түбән дәрәҗәдә» булуы белән аңлатырга тырышканнар. Бу – шул чорның идеологиясенә бик хуш килә торган булган». Автор әлеге мәсьәләнең безнең көннәрдә дә дәвам итүен раслый: «Шуннан соңгы чорларда, хәтта хәзерге көндә дә, кайбер галимнәр һинд-европа телләрен өйрәнүдән туган калыпларга бөтенләй башка системада булган төрки телләрдән мисалларны тутыралар-тутыралар да, тулып бетмәсә, «төрки телләрдә бу категория үсеп җитмәгән әле, формалашу чорын гына кичерә» дигән нәтиҗә ясап куялар. Гүяки тел шулай үсә-үсә бер системадан икенчесенә күчәргә тиеш, гүяки безнең телнең морфологиясе формалашып җитмәгән, димәк, тел дә үсеп җитмәгән булып чыга. Мондый караш белән һич кенә дә килешергә ярамый, чөнки аның дөньяга реаль караш белән бернинди дә уртаклыгы юк. Бу караш милләтләрнең үзара тигезсезлеген күпертү идеологиясенең чагылышы булып тора. Димәк, XIX йөз дәвамында һинд-европа телләре грамматикаларына турыдан-туры таянып язылган хезмәтләрдән тәнкыйди генә файдаланырга кирәк» [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 5–6].

XIX гасыр ахыры – XX йөз башларында татар халкы милли теленең үзенчәлеге турында фикерләр әйтелә торган һәм аны фәнни өйрәнү нигезендә языла торган сарыф вә нәхү дәреслекләре басыла. Г. Фәезханов (1887), К. Насыйри (1895), Н.Ф. Катанов (1898), Г. Мөхәммәтҗан (1900), М.С. Өметбаев (1901), Ш. Таһири (1904), А. Мөхәммәдрәхим (1905), Ф. Садыйков (1908), Ш. Иманаев (1910), Х.Б. Кәбутари (1910), Г. Нугайбәк (1911), И. Кондратов (1911), Г. Алпаров (1912), М. Корбангалиев (1912), Х. Гали (1913), Г. Ибраһимов (1914, 1915), Г. Сәгъди (1915), Җ. Вәлиди (1915, 1919), Чыгтай (1918) һ.б. авторларның дәреслек-кулланмалары аеруча игътибарга лаек санала. Әлеге хезмәтләрдә төрки-татар телнең фонетика, шул исәптән графика һәм имляга караган, һәм, әлбәттә, грамматика тармаклары (сарыф вә нәхү) буенча, заман таләбе белән барлыкка килә торган сорауларга җавап эзләнә, алга таба теория булып үстереләчәк фикерләр күтәрелә. Бу хакта академик

грамматиканың керешендә болай диелә: «Гарәп графикасында язылганлыктан, татар милли әдәби теленең бу беренче морфологияләрен өйрәнү, аларның уңай якларын исәпкә алу бездә җитәрлек түгел. Хәлбуки, нәкъ менә шул дәреслекләрдә хәзерге татар әдәби теле морфологиясенең нигез ташлары салынган. Димәк, морфология курсында аларны күрергә, өйрәнергә кирәк, ләкин шулай ук тәнкыйть күзлегенән карап» [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 6–7].

Шушы ук хезмәтләр М.З.Зәкиевнең «Проблемы языка и происхождения волжских татар» исемле монографиясенең, «Татар телен өйрәнү тарихы» бүлегендә тикшерелә, әлеге нигездә татар теле белеме үсешенең төрле этаплары аерып чыгарыла [Закиев, 1986, с. 210–254]. Алга таба «Казанская лингвистическая школа» дигән белешмә-энциклопедик басманың «Казан лингвистик мәктәбе» дигән беренче китабында урын ала [Казанская лингвистическая..., 2008, с. 7–95].

И.Г. Мифтахованың «Развитие грамматической теории в татарском языкознании. Самостоятельные части речи (по татарским грамматикам XIX – начала XX вв.» (1998) исемле кандидатлык диссертациясендә, рус телле грамматикалар белән бергә, татар теле фән буларак тикшерелеп язылган хезмәтләр, махсус рәвештә өйрәнү объекты булып алына. Алга таба хезмәт 2 китап булып басылып чыга. Монографиядә XIX гасырда –XX гасыр башында язылган татар грамматикалары: а) XIX һәм XX йөзнең 10 нчы елларында, рус теле грамматикалары нигезендә, рус телле укучыларга татар телен өйрәтү өчен, ә) күрсәтелгән вакытта, гарәп грамматикалары схемасында, татарларга аларның үз телләрен өйрәтү өчен, б) XX гасырның 10–20 нче елларында татар телендә татар телен фәнни өйрәнү максатыннан, в) XX гасырның 30 нчы елларына кадәр татар һәм рус телләрендә язылган практик грамматикалар дип, дүрт төргә бүлеп тикшерелә. Һәр төргә караган хезмәтләр саналып бирелә, теоретик һәм практик яңалыклары ассызыклана [Мифтахова, 1998, б. 7–10]. Беренче китапта грамматик теориянең үсеше, исем, сыйфат, сан сүз төркемнәре һәм аларның категорияләре өйрәнелә. Икенче китапта фигыль, рәвеш, алмашлык сүз төркемнәре һәм аларның үзләренә хас булган грамматик категорияләре күрсәтелгән хезмәтләрдә ничек итеп тикшерелүе барлана. Шулай итеп, XIX гасыр – XX гасыр башында төзелгән төрле типтагы грамматикаларда мөстәкыйль һәм ярдәмче сүз төркемнәре һәм аларга хас категорияләрнең ничек итеп өйрәнелүе күзаллана. Димәк, грамматик категорияләрнең тел күренеше буларак, диахроник һәм

синхроник планда структур төзелеше-субстанциональ мәгънәсе һәм аның формалашуы күз алдына бастырыла.

Язма истәлекләрнең морфологиясе тикшерелгәндә дә, грамматик категорияләрне тел күренеше буларак күзаллауга игътибар итәргә кирәк булачак, әмма бу очракта грамматик категорияләрнең ничек итеп файдаланылуын билгеләү максат итеп алынганга күрә, аерым авторның, үзе иҗат иткән әсәрендә, гомумтел күренеше булган берәмлекләрне ничек итеп кулланылуын ачыклау сорала.

Грамматик категорияләрнең кулланылышын тел һәм сөйләм күренеше буларак аерып карау, асылда, әдәби язма телне һәм тел, һәм сөйләм (текст) күренеше буларак тикшерү юнәлешендә билгеләнә ала.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр лингвистикасында тел берәмлекләрен, тик торгандагы структур-төзелеше ягыннан өйрәнү белән бергә, субстанциональ мәгънәнең кулланылышындагы, ягъни сөйләмдәге үзенчәлегенә игътибар итәргә кирәклек мәсьәләсе гамәлгә куела башлый. Русистика һәм Европа филологиясендә әлеге катлаулы мәсьәлә, Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучыларның берсе булган Бодуэн де Куртенэ (1845–1929) хезмәтләре белән, аның 1870 елда басылган мәкаләсендә фонема – аваз – хәрефнең функцияләрен аерымлап караудан башлана дип белдерелә. Фонеманың функциясе дигәндә, аның җанлы сөйләмдә морфемалар составында төрлечә «альтернация»ләнеп кулланыла алуы күздә тотыла. Бу галимнең эшчәнлегенә академик В.В. Виноградов: «Для Бодуэна де Куртенэ сущность языка заключалась в речевой деятельности, в речевом функционировании», – дип дип бәя бирә [Виноградов, 1978, с. 110–119].

Шушы ук фикерне татар халкының атаклы галиме К. Насыйриның эшчәнлегенә карата да әйтергә мөмкин. Бу юнәлештә аның җанлы сөйләмә тел белән язма китаби телнең бер үк күренеш булмавын кат-кат ассызыклавына игътибар итәргә кирәк. 1859 елның 16 мартында Н.И. Ильминскийга язган хатында ул болай ди: «Авылга кайтканда, мин ул китапны үзем белән алып кайткан идем. Бәгъзе мужикларга укып күрсәттем. Мин укыганда үзара сөйләшәләр: «Кара әле, сөйләшкән кебек укый», диләр. Хасил, һәркем аңларлык, иншалла. Ул китапны «Мәҗмәгыль әхбар» дип тәсмия кылдым». Алга таба галим: «Мәдәниятле һәрбер адәмнең ике төрле теле булып, берсе анасыннан сөт имгән мөддәтдә үгрәнгән теледер. Икенчесе, дәхи бер остазга тәгълимгә бирелгәч, гыйлем вә фән лөгатьләре белән ачылган теледер», – дип, нәтиҗә ясый. Балага анасы фән телен өйрәтә алмаганга, «замана

балалары әлфаз вә әлкабларның хикмәтеннән мәхрүм калмышлардыр, чөнки телләре гыйлем вә фән теле белән ачылмакдан мәгъзурләрдер», – дип, гыйлем вә фән теле махсус өйрәтелергә тиешлеген ассызыклый [Насыйри, 1892, б. 5]. «Татар авызыннан чыга торган» ун сузык авазның гарәп графемасының өч төрле билгесе белән генә күрсәтелергә мәҗбүр булуы сәбәпле, сөйләмә телнең язуда да чагылыш таба алмавы, ягъни татар телендәге сөйләү белән язуның бер үк күренеш була алмавы мәсьәләсенә туктала [Насыйри, 1895, б. 3]. Шулай итеп, К. Насыйри, үзенең чордашлары һәм Казан лингвистика мәктәбенең дөньякүләм күренекле вәкилләре булган И.А. Бодуэн де Куртенеэ (1845–1929), Н.В. Крушевский (1851–1887), В.А. Богородицкий (1857–1941) белән бер үк вакытда диярлек, җанлы сөйләмә телнең язуда чагылыш таба торган әдәби тел белән тәңгәл күренеш булмавын ачыклый. Шул рәвешле, татар язма әдәби телен, халыкның сөйләмә теленнән аерып карарга кирәк, дигән фикер мәйданга куела.

Тел берәмлекләрен тел һәм сөйләм күренеше дип дихотомияләп тикшерү эше Женева университеты профессоры Фердинад де Соссюрның (1857–1913) «Курс общей лингвистики» (1916) хезмәтендә теория-принцип буларак күтәрелә: «...язык одновременно и орудие и продукт речи. Но все это не мешает языку и речи быть двумя совершенно различными вещами ... .Речевая деятельность, взятая в целом, непознаваема, так как она не однородна», – дип, тел һәм сөйләм дигән төшенчә-терминнар аерымлана, аларның мәгънәсе аңлатыла [Соссюр, 1972, с. 46–53, 56–58].

Алга таба сөйләмә тел, язма тел, әдәби тел, әдәби норма дигән төшенчә-күренешләр турындагы фикерләр Казан, Женева, Мәскәү, Прага, Копенгаген, Амстердам һ.б. лингвистик мәктәпләре вәкилләре тарафыннан игътибарга алына һәм төрле яклап тикшерелә. Әлеге өлкәдә телнең функциясе дигән төшенчәнең билгеләнә алуы мөһим ачыш булып санала. Телнең функциясе дигәндә, тел берәмлекләренең аерым типтагы сөйләм максатына яраша алуы күздә тотыла. Сөйләмнең максаты дигәндә, аның җанлы сөйләмә (диалогик) һәм язма (текст) хәлендә булуы истә тотыла. Бу типларның үзләренә йөкләнгән вазифалары булуы аерымлана. Кешеләрнең көндәлек аралашуын барлыкка китерә торган җанлы сөйләмнән аермалы буларак, язма текстларда нигездә җәмгыятьтә бара торган иҗтимагый вакыйгалар яктыртыла. Язма текстларның кайбер төрләре, мәсәлән, кешеләрне дәүләт-хөкүмәт белән бәйли торган документ-эш кәгазьләре, аерым

фән тармагына караган хосусый проблемалар өйрәнелеп языла торган фәнни хезмәтләр, көндәлек матбугатта яктыртыла торган публицистика, чынбарлыкны образлап күрергә мөмкинлек бирә торган матур әдәбият, рухани-иманлы булырга өндәүче дини-дидактик текстлар һ.б., аерым сөйләм типлары буларак бүленеп, әдәби телнең функциональ стильләре дип терминлаштырыла. Шул рәвешле функциональ стильләр һәм аларның системасы өйрәнелә башлый. Әдәби телнең функциональ стильләре таләбенә туры китереп, сайланып алына, аларны формалаштыра һәм яшәтә торган тел берәмлекләре милли телнең структур-субстанциональ нормаларының структур-функциональ вариантлары буларак яшәеш ала Әлеге нигездә гомумхалык теле һәм әдәби тел дигән бүленеш-дифференциацияләнү барлыкка килә [Березин, 1979, с. 295–344]. Шулай итеп, функциональ лингвистиканың Прага мәктәбе галимнәре әдәби телнең структур-төзелешен тикшерү барышында, аның социаль-иҗтимагый һәм функциональ-стилистик табигате булган төрле системалардан торуын аңлыйлар. Телнең функциясе дигәндә, тел берәмлекләренең субстанциональ халәттән, сөйләм максатына ярашу өчен, функциональ халәткә күчә алуы күздә тотыла. Төрле функция үти торган сөйләм булгач, димәк, шул функцияне барлыкка китерә һәм яшәтә торган тел берәмлекләренең булуы ачыклана һәм аларны тикшерү зарурлыгы күтәрелә. Тел берәмлекләренең функциясен язма сөйләм (текст) нигезендә өйрәнергә мөмкин булуы ачыклана. Аерым текстта тел берәмлекләренең төп мәгънәсен күзалларга һәм шул мәгънәнең төрле максат белән кулланылганда нинди эш башкаруын (функциональ вазифасын) махсус рәвештә аерып карарга кирәклеге ассызыклана.

Телне системалы-структур һәм функциональ-стилистик яктан өйрәнү XX гасырда төп принцип итеп күтәрелә. Телнең үсеше дигәндә, аның кулланылышының – функциясенең үсеше-киңәюе дип аңларга кирәклек күздә тотылуына басым ясала. Бу яктан караганда, фонетика һәм лексика тармагында, язма традициянең дәвам иткән хәлдә, сөйләмә тел берәмлекләренең дә әдәби тел вазифасын үтәү өчен файдаланылуы, морфология тармагында исем сүз төркеменең сыйфат һәм рәвеш сүз төркемнәре белән узышып, аергыч һәм хәл функциясендә килә алуын тану истә тотыла [Березин, 1979, с. 240–245].

Төрки телләргә караган хезмәтләрдә әлеге мәсьәләләр тагын да тәгаенләнә. Хәзерге тюркологиядә ул, сөйләмә һәм язма әдәби телнең табигате һәм вазифасын тәңгәл күренеш итеп карарга ярамаганлыгын

аңлатудан башлана. Язма әсәрләрнең теле һәм гомуми тел төзелеше өйрәнелә торган тармакларның тарихын берсен икенчесеннән аерып карарга кирәклек көн тәртибенә куела. Бер үк чыганакларга нигезләнеп, бер үк ысул белән тикшерелгәндә, аларның үзләренә хас булган асыл табигате ачыла алмавы аңлатыла. Традицион төрки, иске татар телендә язылган текстларга, татар әдәби теле тарихы тикшерелгәндә генә нигезләнергә мөмкин булу, хәзерге татар теле тарихын турыдан-туры төркигә бәйләп билгеләргә мөмкин булмавы кебек мәсьәләләр конкрет мисаллар белән аңлатыла [Серебренников, 1981, № 4, с. 4].

Бу яктан караганда, әдәби телнең тарихын тикшерү барышында, аның 1) эшкәртелү-шомартылуын, 2) функциональ-стилистик вариантлылыкка, 3) норма вариантлылыгына ия булуын, 4) диалектларыннан өстенлеген, 5) дәвамчылыгы-традициясе булуын аңлап эш итәргә кирәклек ассызыкланды. Шулай итеп, әдәби тел тарихы – милли телнең үзенчәлекле бер тармагы булуы, үзенә хас булган метод-ысул белән өйрәнелергә тиешлеге расланды, әмма бер генә төрки телнең дә бу нигездә тикшерелмәве билгеләнде [Тенишев, 1988, б. 44].

Әдәби тел тарихының җитәрлек дәрәҗәдә тикшерелмәгән булуы татар филологиясендә дә ачык күренә. Бу өлкәдә озак еллар эшләгән галимнәр үзләре дә бу тармакның җитәрлек өйрәнелмәгән булуын ассызыклыйлар. Бер яктан XX гасырның 40нчы елларыннан башлап Л. Җәләй тарафыннан тарихи фонетика, тарихи морфология, татар әдәби теле тарихы буенча студентларга лекция курслары укыла, аерым хезмәтләр басылып, озак еллар буена дәреслек-кулланма буларак файдаланыла (1947, 1953, 1954). Ул хезмәтләрдә авторның нәзари (теоретик) фикерләре ассызыклана, тарихи морфологиянең максат-бурычлары билгеләнә, бихисап тарихи фактик материалга нигезләнеп, сүз төркемнәре һәм аларның аерым категорияләренә хас булган грамматик формаларның барлыкка килү тарихы күзаллана. Әлеге хезмәтләргә нигезләнеп, «Татар теленең тарихи грамматикасы» буенча махсус программа һәм күнегүләр төзелә һәм укытыла.

Бу эшләр алга таба да дәвам ителә: татар язма әдәби теленең төрле чорларга бүленеше тәгаенләнә, һәр дәвердәге иҗтимагый-сәяси хәлләр, әдәби мохит, язмачылыкка караган мәсьәләләрне гомумиләштерү юнәлешендәге хезмәтләр языла, әдәби телнең стильләре тарихы һәм аларның системасы күзаллана (Җәләй, 1958; Фасеев, 1966; Курбатов, 1971, 1978; Зәкиев,1991 һ.б.), «Татар әдәби теле тарихы» курсының программасы (Хаков, 1988), дәреслек-кулланмалары төзелеп (Хаков,

1972, 1993, 2003), берөзлексез укытылып килә. Шул ук вакытта, В.Х. Хаков: «Бүгенге көндә халык тарихын, тел тарихын дөрес, объектив яктырту көн тәртибенә килеп басты», – дип язып чыга [Хаков, 1992, б. 27].

Бүгенге көндә иске татар телендә язылган барлык чыганаклар да диярлек телчеләр, әдәбиятчы һәм тарихчы галимнәр тарафыннан өйрәнелгән. Әлеге өлкәгә караган мәсьәләләр күпсанлы хезмәтләрдә яктыртылган. Ләкин XX гасырның соңгы елларында, галимнәр тарафыннан хәзерге татар филологиясендә телнең структур төзелеше барлана торган тармакларының тарихы да, язма әдәби тел тарихы да объектив фәнни югарылыкта, канәгатьләнерлек дәрәҗәдә тикшерелмәгән дип белдерелә һәм моның кайбер сәбәпләре күрсәтелә. М.З. Зәкиев болай дип яза: «Татар теленең формалашуын төрки-татар юнәлешендә өйрәнү һич тә канәгатьләнерлек түгел. Моңа кадәр без күбрәк язма әдәби телнең тарихын өйрәнү белән шөгельләндек, чөнки ул язып куелган, аны тотып алып, күреп өйрәнеп була, ә сөйләмә телнең формалашуы буенча бездә әле хезмәтләр юк дәрәҗәсендә» [Зәкиев, 1998, б. 525–527].

Л. Җәләйнең тарихи морфологиягә караган кульязмаларын редакцияләп матбугатка әзерләгән Ф. Фәсиев, татар теленең дә, шул исәптән, язма истәлекләренең дә, тарихи планда җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуына игътибар итә: «Л. Җәләйнең “Татар теленең тарихи фонетикасына караган материаллар”ы чыгарылган иде (Казан, 1957). ... Татар теленең тарихи морфологиясе буенча бу хезмәт – беренче тәҗрибә. Гомумән тюркологиядә дә, татар тел белемендә дә мондый хезмәтләр бик аз. Шуңа күрә беренче тәҗрибә буларак, аның бәхәссез уңай яклары – уңышлары да, объектив һәм субъектив авырлыклар белән бәйле кимчелекләре дә булуы мөмкин. Мәсәлән, татар теле тарихына караган чыганакларның, язма истәлекләрнең җитәрлек эшкәртелмәве, фәнни басмаларның аз булуы зур кыенлыклар тудыра, төрле дәвер, чор, гасырлар буенча күрсәтмә мисаллар җитеп бетми, аларның эшләнеше тигезсез чыга, берсенә материал күп, икенчесенә сыеграк була һ.б.» [Фасеев, 2000, б. 4].

Бу фикерләргә кадәр үк, озак еллар буена язма истәлекләрнең җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәвенең башка сәбәпләре булуына игътибар ителә. И.А. Абдуллин, мәсәлән, аерым язма әсәрләрнең ничек итеп өйрәнелүен санап биргәч, болай дип нәтиҗә ясый: «Әмма алар XV йөздән XX йөз ахырына кадәрге төрле жанр һәм чор язма истәлекләреннән торган татар әдәби теле тарихының аерым кисәкләрен

генә тәшкил итәләр. Хәлбуки, теге яки бу чорның әдәби телен һәм гомумән әдәби тел тарихының, лексик-семантик һәм грамматик нормалары үсеш-үзгәрешен язма истәлекләрне алдан килешенгән методика һәм тотрыклы схема буенча өйрәнгәндә генә күз алдына китереп бастырырга мөмкин» [Абдуллин, 1992, б. 11].

Шулай итеп, язма истәлекләрнең телен һәм татар әдәби теле тарихын канәгатьләнерлек дәрәҗәдә өйрәнү өчен, тикшерүнең ныклы система нигезендә, әдәби язма текстның табигате һәм вазифасы ачыла торган методика белән алып барылырга тиешлеге аңлашыла. Методика дигәндә, язма текстта кулланыла торган тел берәмлекләренең структур-системасын аңлап, күз алдында тоткан хәлдә, субстанциональ мәгънәнең ничек итеп файдаланылуын күрсәтү зарурлыгы истә тотыла. Моның өчен беренче чиратта, язма традиция-норманың ни дәрәҗәдә саклануын күз уңында тоткан хәлдә, аның ни өчен һәм нинди вариантлары белән яңартылуына игътибар итәргә кирәк. Язма традиция-норманың ни өчен һәм ничек яңартылуы күзәтелгәндә, авторның сайлаган темасы-максаты, әсәренең жанр-стиле нинди булуын, кайсы укучыны (адресатны) күздә тотып язуын һәм аңа карата нинди мөнәсәбәттә булуын билгеләү сорала.

Шуның белән бергә, традиция-норманың дәвам ителеше һәм вариантлылыкның барлыкка килү мәсьәләсе тикшерелгәндә, аның уртак нигезе һәм телнең һәр тармагында чагылыш таба торган үзенчәлекләре игътибарга алынырга тиеш. Уртак нигез дигәндә, гасырлар буена дәвам итеп килә торган төрки телнең, абруйлы һәм халыкчан булып, аерыла торган параллель ике юнәлештә баруы, һәр тармакның үзенчәлеге дигәндә, әлеге тармакларда телнең төрле өлкәсенә караган максат-бурычларның таләбе истә тотыла. Әдәби язма телнең фонетика тармагында норма һәм вариантлылык мөнәсәбәте, сузык һәм тартык авазларның гарәп графемасы белән язуда чагылышы тикшерелү уңаенда яктыртылды. Гарәп һәм фарсы алынмалары катгый рәвештә үз чыганак теленең графикасы һәм кагыйдәсе белән язылганлыктан, төп игътибар төрки-татар сүзләрендәге сузык һәм тартык авазларның язылышын өйрәнүгә бирелде.

Әдәби язма телнең морфология тармагында, гомуммилли телдәге кебек үк, грамматик категорияләр өйрәнелә. Бу очракта, әлеге категорияләрнең структур системасын күзаллау белән бергә, аларның, ягъни грамматик мәгънә һәм грамматик формаларның, язма текстта ничек итеп файдаланылуын анализлау максат итеп алына. Анализ-

лау барышында гарәп-фарсы алынмаларының төрки-татар теленә хас булган грамматик формалар алып кулланылуы мәгълүм булды. Шуңа күрә, фонетика тармагыннан үзгә буларак, бу очракта, гарәп-фарсы алынмаларын һәм төрки-татар сүзләрен берсен икенчесеннән аерып карарга мөмкин булмавы аңлашылды. Димәк, текстта чагылыш тапкан алынмаларны, төрки-татар сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә тикшерү, ягъни норма һәм вариантлылык мәсьәләсен шушы нигездә хәл итү сорала. Норма һәм вариантлылык мәсьәләсе һәр сүз төркеменең һәр категориясенә мөнәсәбәттә каралырга тиеш. Мәсәлән, исемнең сан категориясендә, күплек санын белдерә торган *-лар/-ләр* күрсәткече, төрки-татар сүзләренә генә түгел, гарәп теле алынмаларына да кушыла, соңгылары, үз чиратында, гарәп теле өчен хас булган «ватык» күплек формасында да кулланылалар. Бу үзенчәлек тартым категориясе өчен дә хас. Алар традиция булып килә торган язма норма һәм норма вариантлылыгын билгеләүдә үзенә күрә бер җирлек булып торалар. Шуның белән бергә исем сүз төркеменең килеш категориясендә һәм фигыль наклонениеләрендә норма вариантлылыгы угыз һәм кыпчак телләренә хас үзенчәлекләр нигезендә дә барлыкка килә. Норма, яисә вариантларының берсенең сайланып алынып, ешрак кабатлануы функциональ-стилистик вариантлылыкны барлыкка китерә. Текстны өйрәнү барышында, әлеге мәсьәләләрне тәфсилләп аңлату сорала.

Шулай итеп, уртак нигезне күзаллаганда, төрки-татар һәм гарәп-фарсы алынмаларының үзара мөнәсәбәте белән бергә, төрки гаиләдәге аерым телләрнең үзенчәлекләрен дә истә тотарга кирәк булуы аңлашыла. Әмма язма традиция-норманың дәвам ителеше һәм вариантлылык барлыкка килүнең уртак нигезе дигәндә, беренче чиратта әлбәттә, төрки телнең, гарәп һәм фарсы алынмаларының ни дәрәҗәдә кулланылуы ягыннан караганда, берсе икенчесеннән XI–XII гасырлардан ук аерымлана торган параллель ике юнәлештә баруы күз алдында тотыла. Әлеге юнәлеш фонетика, морфология, лексика тармакларында традиция һәм вариантлылык күренешләрен күзаллау өчен үзенчәлекле җирлекне тәшкил итә.

Төрки телдәге аерымлану Йосыф Баласагуниның «Котадгу белек» (XI г.) һәм Әхмәд Ясәвинең «Диван-и хикмәт»е (XII г.) кебек мөселман идеологиясен пропагандалучы беренче әсәрләрдән башлана. Галимнәр белдергәнчә, «Котадгу белек» Караханидлар империясендә (840–1212) ханнар ханы булган Тавгач (Тафгач) – Кара Бограхан хакимлек иткән вакыттагы бограхан язма әдәби телендә [Кононов, 1982, с. 502–506],

ягъни гарәп һәм фарсы алынмалары һәм Орхон-Енисей язмаларыннан килә торган китаби-традицион сүз һәм сүзформалар белән баетылган, караханид-бограхан-аристрокат төркидә язылa [Благова, 1977, с. 99–100, Нуриева, 2004, б. 35]. Әхмәд Ясәвинең «Диван-и хикмәт»е һәм Сөләйман Бакырганиның «Бакырган китабы» һәм башка әсәрләре «киң катлам төрки кавеменә аңлаешлы» әдәбиләштерелгән халыкчан сөйләмә телдә, билгеле бер дәрәҗәдә «алынма сүзләрдән арындырылып, җирле сөйләм закончалыкларына таянып барлыкка килгән» төркидә, «Кыйссаи-Йосыф» дастан-поэмасы (1233) әлеге ике төрки юнәлешнең чагылышында иҗат ителә [Татар әдәбияты..., 2014, б. 253, 131–132, 144, 187, 253]. Димәк, төрки телнең бер генә төрле булып кулланылмавы һәм аларның үзара мөнәсәбәте XI–XII гасырлардан ук башлана.

Әлеге үзенчәлек төрле бәйләнеш-мөнәсәбәтләр белән алга таба да дәвам ителә. XIV гасыр Алтын Урда чоры әдәбиятында, Рабгузиның «Кыйссас-ел-әнбия» әсәре һәм «Кодекс-Куманикус» сүзлегендә чагылган язма телне шундый ук төрләргә бүлеп карарга мөмкин [Нуриева, 2004, б. 343]; XV–XVI гасырларда Өмми Камал иҗаты, Максудиның «Могҗизнамә», Мөхәммәдъярның поэмалары – абруйлы төрки-классик иске татар телендә, Хәсән Кайгы, Казтуган һ.б. җырау-шагыйрьләр иҗаты XVI гасыр халыкчан юнәлештәге иске татар телендә [Татар әдәбияты..., 2014, б. 20], XVI гасыр ахыры–XVII гасырда Суфи Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин» әсәре – абруйлы иске татар телендә, Мәүлә Колыйның «Хикмәтләр»е – халыкчан юнәлештәге иске татар телендә, «Җәмигыт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә» кебек тарихи истәлекләрнең аерым бүлекләре, аңлы рәвештә әдәбиләштерелеп – фольклорлаштырып язылганга күрә [Татар әдәбияты ..., т. II, 2014, б. 205–206, 209], традицион абруйлы төрки телнең сөйләмә вариантына якынайтыла; XVII гасыр ахыры–XVIII гасырда Батыршаның «Гарызнамә»се, «Мәҗмугыл хикәят», «Рисаләи Газизә», Г. Утыз Имәнинең башлангыч чор иҗаты – гарәп вә фарсы алынмалары мул кулланыла торган классик-абруйлы иске татар телендә, «Илаһи бәетләр» халыкчан юнәлештәге иске татар телендә иҗат ителә. Кабатлап әйтергә кирәк, бу авторларның барысы да үзләренең әсәрләрен төрки телдә язылуын искәртә баралар. Димәк, язма традиция дәвам ителә дигәндә, төрки-татар теленең гасырлар буена килә торган абруйлы һәм халыкчан төрләре булуын, өйрәнелә торган әсәрдә әлеге төрләрнең кайсысының нигез итеп алынганлыгын һәм ничек итеп үз чорына яраклаштырылуын күрсәтергә тиеш булабыз.

Әлеге мәсьәләне аңлауның кыенлыгы шунда, авторлар үзләре төрки телне абруйлы, яисә халыкчан дип аерымлап бармыйлар, бары тик төркидә языла дип белдергәндә, асылда, традицион рәвештә әсәрнең гарәп яисә фарсыда язылмавы искәртелә. Шуның белән бергә тагын, татар филологиясендә төрки тел дигән төшенчә халыкка аңлашылмый, «ул корама тел булган» дигән фикер аңга сеңдерелгән. Хәзерге вакытта әдәбиятчы галимнәр язма әдәбиятны өйрәнгәндә, еш кына теге яки бу әсәр саф татар телендә язылган дип баралар. Бу очракта хәзерге татар теле истә тотыла, нәтиҗәдә язма традиция инкарь ителә [Татар әдәбияты..., т. II, 2014, б. 2, 20, 74, 219]. Димәк, язма истәлекне тикшерә башлаганда, аның нинди төркидә иҗат ителүен аңлата белергә, әлеге аермалыкның әсәр телендә ничек чагылыш табуын һәм ни өчен яңартылуын (вариантлануын) күрсәтә белергә тиеш булабыз.

Яңартылуның сәбәпләре һәр чорның иҗтимагый тормыш таләпләренә җавап бирү юнәлешендә язылган әдәбиятның телендә чагылыш таба. Мәсәлән, «Җәмигыт-тәварих» (1602) һәм «Дәфтәре Чыңгызнамә» (1660) әсәрләре Казан ханлыгы җимерелгәч, килеп туган төп проблеманы хәл итүгә, ягъни XVII гасыр дәвамында халыкның үз дәүләте булган заманнардагы хәтерен саклау максатын күз уңында тотып язылa. Шулай итеп, әлеге тарихи чыганаклар, авторлар үзләре билгеләгәнчә, Казан төркиендә, ягъни классик-абруйлы язма традиция дәвам ителгән хәлдә, халыкның сөйләмә теленә якын итеп, аңлы рәвештә фольклорлаштырып язылa. Әдәбиятчы галим М. Гайнетдинов белдергәнчә, «Җәмигыт-тәварих» – татар әдәбиятының «Кыйссасел-әнбия», «Могҗизнамә»ләре форматындагы терәк әсәрләрнең берсе. Ул – имансызлыкка илтә торган белемсезлек, китапсызлык, мәгърифәтсезлеккә каршы аяклану, ярсу, катгый каршылык күрсәтеп, җәмәгатьчелеккә аларга каршы радикаль проект тәкъдим итү рәвешендә мәйданга килә [Татар әдәбияты ..., т. II, 2014, 2, б. 205].

XVIII гасыр ахыры – XIX гасырның уртасына кадәр язылган поэзия әсәрләрендә, аннан соң XX гасыр башына кадәр иҗат ителгән әдәбиятта гасырлар буена Болгар-Казан шивәсе дип аталып килгән төрки телнең вазифасы-функциясе тагын да киңәя, нинди максатны күздә тотып иҗат итүгә карап, аның кулланылышында аерымлану-вариантлылык тагын да көчәя: а) адресатның кем булуына аңлы рәвештә иҗтимагый-сәяси мотив дәрәҗәсендә мөнәсәбәт белдерелә; ә) халыкчан сөйләмә телнең колачы киңәйтелә; б) төрле авторның төрле әсәрендә файдаланыла торган ике төрдәге төрки тел, бер үк авторның төрле

әсәрендә файдаланыла башлый; в) төрле жанр-стильләрнең үзенчәлеге тулырак чагылыш таба; г) сәнгатьле прозада хикәяләү алымының үзгәрүе язма телдән файдалануга тәэсир итә. Классик иске татар теленең мөмкинлеге, төрле әсәрдә төрле дәрәҗәдә, сөйләмә тел һәм авыз иҗаты әсәрләре теленә хас халыкчан формалар белән бергә кушыла, нәтиҗәдә, төрки-татар телен төрле вариантта файдалану хасил була. Галимнәр әлеге үзенчәлекне әдәби телнең берничә тибы-агымы дип белдерәләр [Курбатов, 1992, б. 21]. Язма әдәби тел төрле мәгънәдәш сүзләр белән исемләнә килеп, татар әдәби теле дигән атамасы белән ныгый [Языки мира..., 1997, с. 126].

Адресатның кем булуына иҗтимагый-сәяси мотив дәрәҗәсендә мөнәсәбәт белдерелү мәсьәләсе, әдәбиятчы галимнәр фикеренә күрә, Г. Утыз Имәни иҗатында ачык чагыла. М. Гайнетдинов болай дип яза: «Тел мәсьәләсендә Г. Утыз Имәни XIX гасыр татар әдәбиятындагы үзенчәлекле бер күренешне яңартып җибәрүчеләрдән булды. Ул указ алган муллаларны «гами»ләр-наданнар дип атап, үзенең галимлек сыйфатларын исбатлап, элекке традицияләрне көчәйтеп, әсәрләрен гарәп, фарсы сүзләре белән чуарлый, аерым урыннарда бөтенләй фарсыча сөйләмгә күчә. Мондый стиль башка язучылар иҗатында да активлашып китә. Нәтиҗәдә, XIX йөзнең беренче яртысында әдәби тел гадәттән тыш авыр аңлаешлы, чуар бер төскә керә» [Гайнутдинов, 1985, с. 64]. Әдәби телне, «гами муллалар аңламаслык» хәлгә китереп, иҗтимагый-социаль нигездә махсус рәвештә катлауландыру үзенчәлеге, XIX гасырның беренче яртысында иҗат иткән Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки, бераз соңрак Г. Чокрый иҗатларында дәвам итеlә. Бу авторларның барысы да диярлек Көнчыгышның бай мәдәниятен, әдәбиятын, гарәп һәм фарсы теленең, традицион төркинең барлык нечкәлекләрен үзләштергән шәхесләр буларак, үз чоры өчен дә, киләчәк буыннар өчен дә актуаль булган катлаулы публицистик трактатлар иҗат итә. Әсәрләренең күбесе урта гасырларда яшәгән дин һәм хокук буенча күренекле белгечләрнең дөньякүләм танылган хезмәтләренә нигезләнеп языла. Авторлар үзләренең югары дин әһелләре булган остазларын зурлап, фикерләрен Аллаһы Тәгалә, Коръәне Кәрим сүзләре белән куәтләп, һәр шәхеснең әдәп-әхлаклы, тирән ихтирамга лаек булуын, алардан үрнәк алып, гыйлем эстәргә кирәклеге турында язалар. Аңлашылганча, бу әсәрләр укымышлы, белемле, гарәп вә фарсыны яхшы белгән укучыларны күздә тотып абруйлы төркидә иҗат ителәләр.

Шуның белән бергә, XIX гасырның урталарына таба XVIII гасырдагы «Илаһи бәйетләр»дәге кебек халык авыз иҗаты әсәрләрендә кулланыла торган сүз һәм сүзформаларны эзлекле файдаланып, халыкчан төркидә иҗат итү эше җанлана. Шагыйрь Баһави фарсы телендәге «...йыры күп булмаган, сүзе моңлы булган» әсәргә нигезләнеп, татар һәм казак фольклорының тәэсире көчле булган «Бүз йегет» китабын яза [Гайнутдинов, 1985, с. 164–170]. Баһави «...моңлык адәмләрнең күңеле ачылсын...», – дип башлаган юнәлеш Г. Кандалый иҗатында мәхәббәт лирикасы кысаларында дәвам итә. XIX гасырның икенче яртысында, Баһавиның «Бүз йегет китабы» һәм Г. Кандалыйның ялкынлы мәхәббәт нәзымнарын файдаланып, Ә. Уразаев-Кормаши үзенең «Кыйссаи Бүз йегет» (1874) һәм «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1879) әсәрләрен иҗат итә. Автор кыйссалары язылган татар телен үз төбәгендәге атамасы белән нугай дип, казак теле белән катнаштырып язуын ассызыклый, шулай итеп, иске татар теленең, шагыйрь иҗат иткән урынчалыкта кулланыла торган сүз һәм сүзформалар белән баетылуы, Баһави поэмасы белән чагыштырганда тагын да арта төшә. Алга таба әлеге юнәлеш М. Акмулла, Я. Емельянов һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләрендә үзенчәлекле рәвештә дәвам итә. Бу авторлар үзләренең иҗатында, татар халкының гомумсөйләмә тел берәмлекләре белән бергә, үзләренең туган ыруы – кабиләсе (Акмулла үзе белдергәнчә – мишәр, Емельянов – керәшен), яисә яши торган урынчалыгына хас булган (казакбашкорт һ.б.) сүз һәм сүзформаларын да табигый бер җиңеллек белән файдалана, аларны тасвир чарасы итеп күтәрә, нәтиҗәдә, сәнгатьле сөйләм аерым шәхеснең үзенчәлеге белән баетыла, укучыларның даирәсе, димәк язма телнең колачы да киңәйтелә бара [Бәширова, 2007, б.181]. Шулай итеп, иҗтимагый тормыштагы вакыйга-хәлләргә бәйле рәвештә, әсәрнең кайсы укучыга багышлап язылуына карап, XII–XIII гасырлардан ук дәвам итеп торган тезмә-шигъри әдәбиятның, XIX–XX йөз башларында, беренчедән, гарәп-фарсы алынмалары белән баетылган традицион гомумтөрки нигездә, икенчедән, халыкчан-сөйләмә нигездәге төркидә чиратлашып иҗат ителүе күренә.

Алга таба әлеге үзенчәлек яңартылып дәвам итә. Төрле авторның әсәрләрендә куллаланыла торган ике төрдәге төрки телне бер үк шагыйрь үзенең әсәрләрен язганда файдалана башлый. Моның ачык чагылышы Г. Кандалый иҗатында күзәтелә: «Беренче әсәрләрен ясалма телдә язудан башлаган шагыйрь әдәби эшчәнлегенең соңгы чорын-

да халык теленнән аерылмаслык дәрәҗәдә гади итеп язу югарылыгына күтәрелде. Бу юнәлештә шагыйрьгә төп таяныч булып халык авыз иҗаты әсәрләре хезмәт иткәнлеге бәхәссез ... Бу күренеш исә Г. Кандалый иҗатының бер гомер дәвамында төгәл ике чорны иңләп алуын барлыкка китерде», – дип яза М. Госманов Г. Кандалый поэзиясенең теле турында [Кандалый, 1988, б. 51, 63].

Әлеге үзенчәлек Г. Тукайның башлангыч чор иҗатында да күзәтелә. Шагыйрь «Мужик йокысы», «Дусларга бер сүз», «Яз галәмәтләре», «Кечкенә генә бер көйле хикәя», «Көз» шигырьләрен халыкчан сөйләмә – «мужик» сөйли торган тел белән яза. Шул ук вакытта иҗат ителгән «Голумең бакчасында...», «И каләм», «Фикер» газетасына гына махсус түгел», «Пушкинә», «Газета мөрәтипләренә», «Мөхәрриргә» һ.б. әсәрләрендә кулланыла торган сүзләрнең яртысыннан күбесен гарәп һәм фарсы алынмалары тәшкил итә, чөнки аларны автор укымышлы кешеләргә багышлап абруйлы төркидә иҗат итә [Бәширова, 2016, б. 74–82].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында иҗат ителгән проза әсәрләрендә дә әлеге үзенчәлекнең, билгеле бер яңалык белән, дәвам ителүе күренә: бер үк әдип, тасвирлана торган темасының нинди булуына һәм кайсы укучыны күздә тотып язуына карап, иске татар теленең төрле вариантын иркен файдаланган.

Аерым әдипләрнең, мәсәлән, З. Бигиевнең романнары, Р. Фәхретдиннең «Тәрбияле ана», «Тәрбияле балага» исемле дини-дидактик хезмәтләре һәм «Гыйльме әхляк»тан башка аерым җөзьәләре «...ана телендә язылмышдыр», яисә «...төрки таныган балалар аталарына укып күрсәтмәк өчен» дигән искәрмәләләр белән басыла. Ф. Кәрими барлык повестьларын, С. Максуди «Мәгыйшәт» дигән хикәясен татар укучысына багышлыйлар, димәк, татар халкының җанлы сөйләмә теленә якын итеп язарга тырышалар.

Шул ук әдипләрнең тулаем төрки дөнья укучысы укып аңласын дип язган хезмәтләре (мәсәлән, З. Бигиев һәм Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләре, Р. Фәхретдиннең «Шура» журналында басылган күпсанлы мәкаләләре һ.б., М. Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» хикәясе) барысы да иске татар теленең җәдиди-госманлы вариантында, ягъни угыз формалары мул кулланылып иҗат ителә.

Р. Фәхретдин, Ш. Мәрҗанинының гарәп телендә язылган биобиблиографик хезмәтен дәвам итеп, ике җилд, 14 җөзьәле «Асар»ен (1900–1908), 344 хәдискә аңлатма-шәрех рәвешендә төзелгән

«Җәвамигуль Кәлим шәрхе»н (1916) һ.б. дини-тарихи хезмәтләрен иске татар теленең гарәп вә фарсы алынмаларын һәм традицион-язма формаларын мул файдаланып язган. Ф. Кәриминең дини-тарихи дәреслекләре дә шушы юнәлештә төзелгән.

Шулай итеп, әлеге әсәрләрдә адресатның кем булуына бәйле рәвештә бер үк төшенчә берничә исем белән, ягъни традицион-төрки, татар, төрек, гарәп, фарсы сүзләре белән атала һәм бер үк грамматик мәгънә дә берничә телгә хас булган форма белән белдерелә алган. Нәтиҗәдә, төрки-татар язма әдәби теле үзенчәлекле структурфункциональ, ягъни, терминлаштырып әйткәндә, норма вариантлылыгы халәтендә хәрәкәт иткән.

Өйрәнелә торган чорда бу үзенчәлек тагын функциональ-стилистик вариантлылык дип атала торган күренеш белән бергә үрелә. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар язма әдәби теленең барлык функциональ стильләре дә (матур әдәбият, сәяси-публицистика, дини-дидактика, фәнни-танып белү, рәсми эш кәгазьләре, эпистоляр-хат, көндәлек, һөнәри) актив хәрәкәттә була. Бу стильләрнең һәрберсе иҗтимагый тормышта бара торган күп төрле эшләрнең аерым бер төрен алып бару вазифасын үтәү өчен барлыкка килгән, озак гасырлар дәвамында калыплашкан сөйләм типлары булып тора. Әлеге типлар гомумән сөйләмне хасил итәргә тиеш дип санала торган төп күрсәткечләре (фикернең оешуы һәм хәбәр ителүе, сөйләүче мөнәсәбәтенең белдерелүе) ягыннан караганда, берсе икенчесеннән шактый аерыла, һәрберсенең үзләренә хас булган үзенчәлекләре була. Бер яктан, телдән файдалану һәр стильнең таләбенә буйсына, икенче яктан, әлеге таләп телнең структурасына да үзенчә тәэсир итә, ул лексик-терминологик яктан баетыла һ.б. Әлеге нигездә язма телдә функциональ-стилистик вариантлылылык хасил була. Әдәби телдәге бу үзенчәлекнең бер үк автор иҗатында чагылыш табуы К. Насыйриның киң кырлы эшчәнлегендә ачык күренә [Татар әдәби..., 2015, б. 105–111].

Шулай итеп, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында иске татар теле әдәби телнең табигатен барлыкка китерә торган традициондәвамчанлык, эшкәртелгән-шомартылган, диалектлардан өстен булу кебек сыйфатлары белән бергә, вазифасының таләбе белән, әдәби норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык дигән билгеләре белән дә характерлана. Бу чорда әлеге функциональ-стилистик үзенчәлек иҗтимагый тормышта бара торган әдәби-мәдәни вазгыятькә бәйле рәвештә, аеруча проза жанрында ачык чагылыш

таба. Биредә ул әдәби телнең башка билгеләренә караганда да активрак төс ала, махсус алып тикшерү өчен ныклы материал бирә [Бәширова, 2012].

Шуның белән бергә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы проза әсәрләрендә, хикәяләү алымының (стиленең) төрлелеген дә күз уңында тотарга кирәк. Әдипләрнең чынбарлыкны ничек итеп күрү һәм сурәтләп бирү үзенчәлегенә нигезләнеп, хикәяләүнең төрле ысуллары хасил була. Шул нигездә телдән файдалануда аермалык барлыкка килә. Беренче төр хикәяләү белән Ә. Уразаев-Кармашиның «Кыйссаи Бүз йегет» (1874), «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1879), К. Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы» (1868), «Кырык бакча» (1880), «Әбүгалисина кыйссасы» (1882), «Фавакиһел-җөләса фил әдәбият» җыентыгында (1884) «Кырык рауза» дип тупланган кыйссалар языла. Аларда хикәяләү автор тарафыннан кеше сүзен сөйләүгә нигезләнә.

Сәнгатьле чәчмә әсәрләрдә вакыйганы сөйләп хикәяләүнең икенче төре М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романы белән башлана (1886), З. Бигиев, Ф. Кәрими, Р. Фәхретдин, Г. Гафуров-Чыгтай, Ш. Мөхәммәдов, З. Һади һ.б. язучыларның иҗаты белән дәвам ителә. Әлеге авторлар вакыйгаларны укучысына эндәшә-эндәшә үзләре сөйләп баралар. Әсәрләрнең нигезен авторның үз сүзен сөйләве һәм аны укучысына карата булган мөнәсәбәте тәшкил итә [Бәширова, 1979, б. 7–41].

Әсәр эчтәлеген бирүдәге аермалык тел берәмлекләрен куллануга, аерым алганда грамматик формаларны файдалануга да тәэсир итә: 1) К. Насыйри иҗаты белән тәмамланган чорда әсәрләрдә фигыльнең заман формалары, асылда, үткәндә булган хәлләрне сөйләүгә җайлаштырылган хәлдә файдаланылалар; 2) М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә автор укучысына турыдан-туры эндәшеп, хәзерге заманда үзе күргән вакыйга турында сөйли. Бу очракта фигыльнең һәрбер формасын үзенең туры – төп мәгънәсендә куллану мөмкинлеге ачыла, тартымлы исемнәрнең синтетик төрләре иркен файдаланыла һ.б.

XX гасыр башында хикәяләүнең өченче төренә нигез салына. Аерым алганда бу чорда иҗат ителгән әсәрләрдә, булган хәлләрне турыдан-туры сөйләүгә караганда, күбрәк фикер әйтү максаты куела. Телнең барлык чаралары әлеге катлаулы эшне башкаруга юнәлтелә. Нәтиҗәдә сүзнең мәгънә эчтәлеге билгеле бер әсәр эчтәлеге өчен генә кирәк булган мәгънә төсмере белән баетыла: сүз – сүз-сурәткә әверелә. Бу үз чиратында грамматик формаларның кулланылышына да тәэсир итә [Бәширова, 1979, б. 42–75].

Шулай итеп, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар язма әдәби теле үзенең барлык жанр-стильләрендә хәрәкәттә була, тотрыклы гомумтөрки нигез дәвам иткән хәлдә, региональ сүз һәм сүзформалардан файдалану да киңәя бара, авторларның мөнәсәбәт белдерүләре катлаулана, әлеге нигездә, татар әдәби теле иң нәтиҗәле булган дәверен, алдагы чорларда кабатлана алмаячак алтын чорын кичерә.

Билгеле булганча, дәверләр, чорлар, еллар буена дәвам итеп килә торган төрки-татар телендәге язма текстлар берьюлы берничә фәннең (тел тарихы, халык тарихы, әдәбият, мәдәният, стильләр тарихы һ.б.) фактик базасын тәшкил итә. Әлеге фактик материал һәр фәннең үз максатыннан чыгып, үз метод-ысуллары белән анализлана һәм тикшерелә.

Әдәби тел тарихын өйрәнгән вакытта, гомумтел берәмлекләренең структур төзелешен билгеләү белән бергә, аларның кайсы жанр-стильнең нинди текстында, ни өчен, ни рәвешле һәм нинди ешлыкта кулланылуын, ягъни әлеге тел берәмлекләренең аерым бер автор тарафыннан махсус корылган сөйләме үзенчәлеге буларак файдалануын күзаллау сорала. Шушы таләпкә җавап бирерлек итеп тикшерелгән очракта гына әдәби телнең үзенә хас булган табигате һәм вазифасы ачылачак, әдәби тел тарихын өйрәнү аңа якын булган башка фән тармакларыннан аерылып торачак.

Моның өчен түбәндәге эшләрне башкару зарур: а) күрсәтелгән вакыт эчендә язылган һәм басылып чыккан матур әдәбият стиленең проза, поэзия, драма жанрларына караган әдәби әсәрләрне, шулай ук мөмкин булган дәрәҗәдә, фәнни әдәбият, иҗтимагый публицистика, рәсми-эш кәгазьләре, дини-дидактика, эпистоляр-хат, көндәлек-һөнәри стильләрдәге текстларны табарга, укырга, аңларга; ә) иске татар теленең кулланылышын өйрәнеп язылган хезмәтләрне барларга, аларда күтәрелгән проблемаларга һәм чыганак әдәбиятның ничек итеп өйрәнелүенә игътибар итәргә; б) һәр текстка фонетик, графо-орфографик, грамматик һәм лексик-семантик анализ ясарга; в) нәтиҗәләрне тел тармакларына нисбәтән структур парадигмалары ягыннан гомумиләштерергә, өйрәнелә торган чордагы әдәби телнең нормасын һәм аерым текстларда чагылыш таба торган норма вариантлылыгын билгеләргә; г) тел берәмлекләренең кайсысының аерым текст өчен генә сайланып алынуын һәм нинди махсус вазифа үтәвен ачыкларга, кабатлану ешлыгын билгеләргә, ягъни аларның синтагматик бәйләнеш-мөнәсәбәтләре нигезендә функциональ-стилистик мөмкинлекләрен күзәтергә; д) объ-

ектив яши торган һәм үз чорының иҗтимагый таләпләрен канәгатьләндерә алган әдәби телне сәясәткә җавап бирү йөзеннән барлыкка килгән төрле карашлардан аерып алып, аның өйрәнелә торган вакыттагы чын табигатен, реаль статусын билгеләргә; е) кабул ителгән ныклы бер эзлеклелек саклансын өчен, хәзерге татар әдәби теленең өйрәнелү тәртибен, норма һәм терминологиясен чыгыш ноктасы итеп алырга, җанлы сөйләмә формаларга игътибар итәргә.

Чыганак итеп алынган язма текстларда үз чор әдәби теленең ничек итеп чагылышын күзәтү эше, тел өйрәнү өчен төп метод булып саналган гомумлингвистик тасвирлау һәм барлау ысулына нигезләнде, аерым фактларны табу, теркәү, классификацияләү кебек алымнарны үз эченә алды. Бу эшләр эшләнү уңаенда, өйрәнелә торган чордагы аерым тел фактларын хәзерге гомумхалык татар теле һәм әдәби нормасы белән чагыштырганда, тарихи-чагыштырма метод белән файдаланылды. Төрки-татар һәм гарәп-фарсы телләренең бер-берсеннән аерымлана торган типларын чагыштырып анализлау чагыштырма-типологик методка нигезләнеп башкарылды.

Телне тел системасының берәмлеге буларак өйрәнү телне язма сөйләм (текст) системасының берәмлеге буларак тикшерү ысулы, ягъни функциональ-стилистик метод белән бергә алып барылды. Шул нигездә, язма текстның композицион төзелешенә, һәр стиль-жанр таләбе белән аерым сүзләрнең сайланып алынуы, кабатлану ешлыгы, тег яки бу сөйләм тибына туры килерлек итеп җөмлә төзү һәм язучы мөнәсәбәтенең ничек итеп чагылышы кебек, аерым сөйләм типларын барлыка китерә торган төп компонентларга игътибар ителде. Шулай итеп, аерым бер чордагы язма әдәби тел дигән күренешнең объектив асылы – табигате һәм вазифасы аңлатылды.

Әлеге эшләрне башкарган вакытта тел өйрәнү методлары сөйләм тикшерү методлары белән бергә үрелеп барды. Методологик нигез дигәндә, тел системасы объектив-реаль диалектик үсеш-үзгәрештә яши, ныклы берлек тәшкил итә; гомумхалык теле үзенең кулланылышында социаль яктан аерымлана – дифференцияцияләнә [Общее языкознание, 1979, с. 57–58].

Алда әйтеп үтелгәнчә, классик иске татар теленең аерым чорларында иҗат ителгән барлык язма истәлекләр дә диярлек тарихчылар, әдәбиятчылар һәм телчеләр (Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, Я. Абдуллин, М. Госманов, Р. Әмирханов, М. Гайнуллин, Ш. Абилов, Г. Халитов, Х. Госман, Г. Таһирҗанов, Җ. Алмаз, Ә. Тенишев, И. Нуруллин,

Н. Хисамов, М. Гайнетдинов, М. Әхмәтҗанов, Ф. Яхин, Җ. Зәйнуллин) тарафыннан төрле яктан өйрәнелеп, бу өлкәдә аерым мәкаләләр, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре, монографияләр буларак, басылып килде [Бәширова, 2012, б. 171–173]. Шуның белән бергә, татар теле, язма әдәби тел проблемалары телче галимнәр (А. Самойлович, А. Богородицкий, Л. Җәләй, Ә. Тенишев, Ә. Нәҗип, Б. Серебренников, В. Хаков, Г. Благова, М. Закиев, Х. Курбатов, Ф. Фәсиев, И. Бәширова) тарафыннан махсус рәвештә дә өйрәнелде. Аларның хезмәтләрендә чагылыш тапкан фикерләр аерым әсәрнең тел үзенчәлекләрен тикшергән вакытта гомумтеоретик нигезе итеп алынды.

Озак еллар буена Казан дәүләт университетында «Татар әдәби тел тарихы» курсын укыткан, аның программа һәм дәреслекләрен төзегән В.Х. Хаков белдергәнчә: «…Татар тел гыйлеменең бер тармагы буларак, татар әдәби теле тарихы фәне XX гасырның 60–70 нче елларында формалаша» [Хаков, 2003, б. 5]. Димәк, әдәби әсәрләрнең телен, бу очракта морфология тармагында тикшерелә торган сүз төркемнәре мәсьәләсенең тарихи планда ничек итеп яктыртылуын да, асылда, шушы вакытларда язылган хезмәтләргә нигезләнеп аңлатырга мөмкин.

Биредә сүзне Л. Җәләйнең «Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар)» хезмәтеннән башларга кирәк. Хезмәттә исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль сүз төркемнәре тикшерелә. Һәр сүз төркеменең һәр категориясе тарихи планда яктыртыла, ягъни руникада язылган текстлардан ук китерелгән мисаллар белән аңлатыла башлый һәм хәзерге сөйләмә, әдәби тел үзенчәлекләренә китереп җиткерелә. Күпчелек мисаллар язма текстлардан тупланган, әмма алардан файдалану аерым әсәрләрнең тел үзенчәлеген күрсәтеп, аларның тарихи эзлеклелектә ничек дәвам ителүен ачу юнәлешендә бармый, ә бәлки морфологик категорияләрнең тарихи үсеш-үзгәрешен күрсәтү максатыннан чыгып, тексттан аерып алып сайлана.

Әдәби истәлектә кулланыла торган теге яки бу тел күренешен, шул исәптән морфологик категорияләрне, язма телнең тарихы эзлеклелегендә тикшерү дигәндә, һәр аерым әсәргә «…татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычы» [Җәләй, 1938, б. 59] дип карау һәм шул юнәлештә өйрәнү зарур. Бу очракта истәлекнең теленә, димәк, морфологик категорияләренең форма һәм мәгънәләрен, традиция булып килә торган норманың ни дәрәҗәдә дәвам ителешен һәм ничек, ни өчен яңартылуын күрә һәм аңлата белергә кирәк. Шул вакытта гына һәр аерым истәлекнең гасырлар буена дәвам итә торган язма әдәби тел

тарихының бер буыны булуын күрергә, ягъни анализны дөрес барган дип санарга мөмкин. Язма тел тарихын өйрәнүче галимнәрнең фикерләренә күрә, бу эшчәнлекнең XX гасырның ахырларына кадәр «…максатчан һәм анык бер програмасы» булмавы ассызыклана [Абдуллин, 1992, б. 8–20], татар әдәби теле тарихы объектив-фәнни нигездә җитәрлек дәрәҗәдә тикшерелмәгәнгә, аны яңача өйрәнергә кирәклек көн тәртибенә куела [Татар әдәби теле…, 2015, б.194–205].

Язма истәлекләрне анализлаганда, ныклы система булмаган дип белдерелсә дә, фәнни әдәбиятта аларны өйрәнүдә билгеле бер калып-штампның формалашканлыгы күренә. Тарихи грамматиканы өйрәнүчедән аермалы буларак, язма истәлекне тикшерүче галим текстта кулланылган телне аңлап-барлап, телнең төрле тармакларын бүлеп өйрәнүгә кадәр, күп энергия сарыф итәлә торган гомумфилологик эшләр башкарырга, ягъни кульязмаларны, басмаларны табарга, төрле вариантын чагыштырырга, эчтәлегенең һәм теленең охшаш яисә аермалыкларын ачыкларга, аларның сәбәбен аңлатырга, өйрәнелешен күз алдына бастырырга тиеш. Аңлату дигәннән, иске татар теленең текстлары, төрле чорда төрле дәрәҗәдә, бигрәк тә аристрократ-абруйлы төркидә язылганнары, XX гасыр башына кадәр диярлек гарәп-фарсы алынмалары белән баетылып язылганлыктан, гарәп графикалы текст белән эш итүче телче гомумтөркине һәм иске татар телен генә түгел, табигате ягыннан алардан үзгә булган гарәп вә фарсы телләренең үзенчәлеген, ягъни берничә мәгънәгә ия булган гарәп вә фарсы берәмлекләренең контекстка туры килә торганын билгеләргә тиеш. Язма истәлекләрне өйрәнүчеләрнең барысы да әлеге юнәлештәге эшләрне башкара, димәк, бу нигезнең ныклыгы саклана.

Шулай итеп, язма истәлекләрне тикшерү ныклы программага куелмаган дигәндә, асылда, әсәр эчтәлегендә кулланыла торган тел берәмлекләрен анализлауның принцибы күз уңында тотыла. Язма истәлек тикшерелә торган хезмәтләрне укып барганда, һәр авторның үзенә уңай булган, үзе дөрес дип тапкан юнәлештәрәк эш алып баруы аңлашыла. Аерым авторлар, язма истәлектә кулланыла торган тел берәмлекләрен, телнең фонетика, морфология, лексика тармакларына бүлеп анализлый (Хакимзянов, 1978, 1987; Ахметгалеева, 1979; Хисамиева, 1980; Хисамова, 1981, 1990, 1999; Маннапова, 1982; Мухаметрахимова, 1990; Шамарова, 1991; Ахметзянов, 1991; Алеева, 1993; Исламова, 1998; Гилемшин, 1998, 2001; Нуриева, 1999, 2004; Гайнутдинова, 2004; Миннуллин, 2012; Бахтиев, 2013). Кайбер авторлар

истәлекнең морфология һәм синтаксисын (Юзмухаметов, 2002) яки фонетика һәм лексикасын (Мухаметшин, 2007), кайберләре-фонетик һәм морфологик үзенчәлекләрен өйрәнә (Исхакова, 2005; Абдулхаков, 2010), яисә әсәрләрнең морфологиясе (Бәширова, 1999; Гарипова, 2003, 2010; Юсупов, 2006; Мирхаев, 2008), яки лексикасы гына анализлана (Кузьмина, 2001; Кадирова, 2003; Закирова, 2007) һ.б.

Язма истәлекнең морфологик үзенчәлекләре барлык автор тарафыннан да бер системада яктыртылмый. Аерым авторларның хезмәтендә, истәлекнең грамматик төзелешенә караган үзенчәлекләр хәзерге әдәби тел грамматикасында чагылыш таба торган барлык тема-бүлекләренә туры китерелеп анализлана. Кайбер авторлар аерым сүз төркемнәрен, яисә аларның аерым категорияләрен өйрәнә. Тикшерү ысулында, билгеле бер уртаклык булуы да күзәтелә: күпчелек хезмәтләрдә, өйрәнелә торган истәлекнең морфологик үзенчәлекләрен анализлау барышында, аларның кайберләренең гомумтөркидән килүе искәртелә, шул ук вакытта, хәзерге төрки телләрдә һәм татар халкының җанлы сөйләменә яисә әдәби нормасына якынлыгы ассызыклана[Ахметгалеева 1979, с. 75, 81; Насилов, 1960, с. 28; Насилов, 1963, с. 35]. Шуның белән бергә борынгы язма истәлекләрдән килә торган төрки үзенчәлекләрнең хәзерге татар телендә дәвам ителүе хакында да мәгълүмат бирелә [Ахметгалеева, 1979, с. 76, 78].

Урта гасырларга караган башка истәлекләр, бигрәк тә «Кыйссаи Йосыф» поэмасы тикшерелгәндә, аларның болгар-татар халкына якынлыгы һәм аның теле белән уртаклыгы булуы ассызыклана [Поэт-гуманист Кул Гали, 1987, с 245–252]. Башка авторларның хезмәтләрендә дә тикшерелә торган истәлекнең телен, аерым алганда, аның морфологик үзенчәлекләрен татар теленең диалектлары һәм хәзерге әдәби формалары белән чагыштыру күренә. Нәтиҗәдә язма текстларда файдаланыла торган тел берәмлекләренә мөрәҗәгать ителә, аерым текстта кулланыла торган тел берәмлеге әсәрнең эчтәлегеннән тартып алынып анализлана. Аннан соң аларның, сөйләмә телдә үзгәрү-үзгәрмәве күзәтелә, ягъни тарихи-чагыштырма методка нигезләнеп, телнең тарихи грамматикасы язылa. Галимнәр тарафыннан телнең тарихи грамматикасы язылганда язма текстларга нигезләнеп булмавы, диалекталь үзенчәлекләрнең нигез итеп алынырга тиешлеге ассызыклaныла [Серебренников, 1981, с. 9].

Кыскача бирелгән әлеге мәгълүматлардан күренгәнчә, бу хезмәтләр махсус төзелгән бердәм план-проспект нигезендә тикшерелгән

дип әйтеп булмый: төрле хезмәттә, телнең төрле тармагы өйрәнелә, димәк, телнең барлык өлкәләренә дә игътибар ителми; морфология тармагында һәр сүз төркеменең хосусый грамматик категорияләре тигез дәрәҗәдә тикшерелми. Иң мөһиме, язма истәлек өйрәнелеп язылa торган күпчелек хезмәтләрдә (соңгы елларда язылган докторлык диссертацияләрен искә алмаганда) әдәби тел тарихының үзенә хас булган табигате (традициясе, эшкәртелүе, диалектларыннан өстенлеге) һәм вазифасы (төрле чорда, төрле жанр-стильдә язма традициянең норма вариантлары белән дәвам ителә алуы) ачылырлык метод-ысулның файдаланылмавы, аерым истәлектә язма традициянең ничек чагылышы, норма һәм стиль вариантларының ни өчен барлыкка килүенең сәбәбе дә билгеләнми. Әсәрдә кулланыла торган тел берәмлеге, эчтәлегеннән тартып алынып, асылда, тел күренеше буларак анализлана, сөйләм (текст) күренеше дип аерып карау һәм тарихи үсеш-үзгәреш эзлекле рәвештә күзәтелми.

«Татар әдәби теле тарихы» дигән коллектив монографиянең II томы язылганда, алдарак телгә алынган хезмәтләрдә, сүз төркемнәрен тикшерү барышында чагылыш тапкан фикерләр истә тотылды. Әлеге нигездә язма традициянең ничек дәвам итүен һәм җанлы-сөйләмә сүз һәм сүзформаларының функциональ-стилистик үзенчәлекләрен, ягъни морфология өлкәсенә караган норма һәм вариантлылык мәсьәләсен өйрәнү максаты куелды. Фәнни-тикшеренү эше гарәп графикасында күрсәтелгән иске татар язма чыганакларыннан алынган мисалларга нигезләнеп, автор тарафыннан ничек итеп кулланылуына бәйле рәвештә яктыртылды. Һәр сүз төркеменең үзенә хас булган грамматик мәгънә һәм аны белдерә торган формасының, гасырлар дәвамында, язма традиция буларак тарихи дәвам ителешенә һәм аның, җирле региональ сөйләм теле, диалектларның тәэсире нигезендә, ничек итеп яңартыла баруына игътибар бирелде [Серебренников, 1981, с. 9; Тенишев, 1988, с. 72]. Язма әдәби телнең тарихы өйрәнелгәндә, әлеге катлаулы мәсьәләне ныклы бер нигезгә салу һәм грамматик категорияләрнең субстанциональ, ягъни текстка килеп кергәнче халәтендәге табигый үзенчәлеге турында мәгълүмат бирү максатыннан, аларның хәзерге телдәге өйрәнелүләренә мөрәҗәгать ителде. Һәм, грамматик категорияләрнең гасырлар буена килә торган традициясен күзалларга һәм төрле тип сөйләм эчендәге функциональ күренешләрне билгеләргә мөмкин булды.

## 1. БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕ ЧОРЫ ИДЕЛ БУЕ ТӨРКИ ЯЗМА ӘДӘБИ ТЕЛЕНЕҢ МОРФОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Идел буе төрки теленең үсеп китү чоры шул ук вакытта IX–XI гасырларда Көнчыгыш Европада Урта Идел буенда төзелгән Болгар дәүләте, анда яшәгән кабилә, халык телләре белән бәйләнештә карала. Идел Болгары Көнчыгыш Европаның зур дәүләтләреннән була һәм ул – Идел буе халыклары, аеруча Урта Идел һәм Урал буе татарлары тарихында тирән эз калдырган дәүләтләрнең берсе. Болгар иле үзенең иҗтимагый-икътисади вазгыяте һәм мәдәнияте ягыннан ул чордагы башка Көнбатыш Европа феодаль дәүләтләр белән бер баскычта торган һәм урта гасырлар цивилизациясенең аерылгысыз бер буынын тәшкил иткән [История татар, 2006, с. 621–628]. Идел буе Болгарстанында, галимә Р. Ганиева билгеләвенчә, төрки-болгар-татар Яңарышының мәйданга чыгуы өчен зарури дип саналган алшартлар: дәүләтчелек, күп санлы шәһәрләр, алга киткән һөнәрчелек һәм авыл хуҗалыгы, эчке һәм тышкы сәүдә, төрле диалектларда сөйләшүче төрки кавемнәр өчен уртак әдәби тел, халыкны бербөтен итеп берләштереп торучы монотеистик дин, бихисап мәктәп-мәдрәсәләр, аларга хезмәт итүче күп санлы галим-голәмә һ.б. барысы да була [Татар әдәбияты, 2014, б. 214]. Утраклык, шәһәр тормышының алга китүе, шәрык дөньясы белән тыгыз бәйләнеш Болгарда мәгариф, фән һәм мәдәниятнең үсешенә уңай йогынты ясый. Күпсанлы уку йортларында дөньяви гыйлемнәр, дин, гарәп-фарсы һәм төрки телләр, шәрык авторларының хезмәтләре өйрәнелә. Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителгәч, гарәп язуы гамәлгә кергән, фәнни хезмәтләр гарәп телендә языла башлаган. Гарәп язуын кабул итү Шәрык белән тыгыз элемтә урнаштырырга, болгарларда

әдәбиятны, мәгърифәтне һәм төрле фәннәрне үстерергә ярдәм иткән. X – XII йөзләрдәге гарәп-фарсы дөньясының язма чыганакларында болгар тарихчылары, табиблары, философлары һәм хөкемдарлары турында төрле хәбәрләр очратырга мөмкин. Мәсәлән, әл-Гарнатый Болгар шәһәрендә казый Йакуб бине Ногман язган «Болгар тарихы» китабын укыган. Галим Борһанетдин бине Йосыф дарулар ясау турында китап язган, Урта Азия философларының әхлак-этика турындагы, риторика хакындагы хезмәтләренә аңлатмалар эшләгән [Фәхретдинов, 1996, б. 87].

Гомумтөрки әдәби тел традицияләре һәм җирле тел үзенчәлекләре нигезендә бу чорда Идел буе төрки әдәби теле һәм аның аерым стильләре формалаша: матур әдәбият стиле (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы); үгет-нәсыйхәт стиле («Бәдәвам», «Тәкый гаҗәп», «Нәсыйхәтес салихин», «Ана вә угыл» дастаны); фольклор әсәрләренең теле («Кыйссаи ике былбыл», «Туйбикә кыйссасы», «Нәүрүз бәете», «Сак-Сок бәете» һ.б.); эпитафик язмалар стиле [Татар әдәбияты тарихы, 2011, б. 100]. Тикшерүләребездә мәшһүр шагыйрь Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы һәм «Ана вә угыл» дастаны файдаланылды. Әдәби истәлекләрнең тел үзенчәлекләре Болгар чоры мәдәниятенең бер өлешен тәшкил иткән кабердаш язмалары белән чагыштырылды.

«Кыйссаи Йосыф» әсәренең хәзерге көндә йөз алтмыштан артык кулъязма нөсхәсе дөнья мирасханәләрендә саклана, алар бар да татар укымышлылары кулы белән күчерелгән. Кол Гали әсәрен фәнни өйрәнү тарихына да 175 елдан артык вакыт узган. Поэманың тел һәм стиль үзенчәлекләре төрле чорларда Утыз Имәни, Ш. Мәрҗани, Г. Газиз һәм Г. Рәхим, А. Самойлович, Б.А. Яфаров, Җ. Алмаз, А. Боровков, Ә. Нәҗип, Ә. Тенишев, В. Хаков, М. Зәкиев, Н. Хисамов, Ф. Хисамова, Р. Ганиева, Ф. Хакимҗанов, Ф. Фәсиев, Ш. Абилов, Х. Кузьмина һ.б. тел һәм әдәбият белгечләре тарафыннан өйрәнелгән һәм тикшеренүләр әле дә дәвам итә. Әсәрнең өйрәнелү тарихы Н. Хисамов (1979, 1984, 1996, 2006), Х. Кузьмина (1998, 2001) хезмәтләрендә бик җентекле яктыртылган һәм тулы бәяләмә бирелгән, күзәтүләребездә әлеге хезмәтләргә нигезләндек. «Кыйссаи Йосыф» әсәренең морфологик үзенчәлекләрен тикшергәндә, Утыз Имәни редакциясендәге Кол Гали «Кыйссаи Йосыф» әсәренең 1839 елгы басмасы, Казан федераль университетының сирәк китаплар бүлегендә 546 шифр астында саклана торган нөсхәгә (У.И. нөсхәсе дип

билгеләдек, бит һәм юл санын күрсәттек), 1825 елда күчерелгән Сара Биккол кулъязмасыннан (64 бит) КФУ китапханәсенең сирәк китаплар бүлегендә 546 шифрлы нөсхәгә нигезләндек (С.Б. нөсхәсе). Фазыл Фәсиев әзерләгән тулы критик текстка нигезләнеп [Фасеев, 1983, с. 544], компьютер фонды нигезендә Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф» әсәренең сүзлеген эшләдек, (Ф. нөсхәсе). Сүзлекнең төп өлешен ешлык күрсәткечләре һәм конкорданс, ягъни шигырь юллары рәвешендә китерелгән сүзләр күрсәткече тәшкил итә.

«Ана вә угыл» дастаны татар халкы арасында шактый таралган булган. Хезмәттә А күчерелмәсе буларак билгеләнгән кулъязма нөсхә кирилл графикасында сакланган, 123 бәеттән тора. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә сакланган 39 тупламдагы гарәп күчерелмәләре 2831 (В. нөсхәсе) һәм 3254 (Б. нөсхәсе), Ф.Ш. Нуриева әзерләгән тулы тәнкыйди текст (Н. нөсхәсе) файдаланылды. Болгар чоры язма истәлекләренең телен өйрәнгән галимнәрнең теоретик хезмәтләренә таяндык.

Әдәби истәлекләрнең морфологиясен, алардагы грамматик формаларның кулланылыш үзенчәлеген өйрәнү татар әдәби теленең нигезен билгеләү өчен әһәмиятле. Әдәби истәлекләр тамырлары белән күп гасырлык борынгы төрки, караханлы-уйгыр әдәби телләренә барып тоташа. Шул рәвешле телләрдә әдәби традицион уртаклыклар саклана, шулай ук әлеге дәвердә традицион әдәби телнең үзгәреше белән очрашабыз. Истәлекләрнең грамматик формаларының кулланылышын өйрәнү бу ядкәрләрдә чагылган әдәби телнең диалекталь нигезен билгеләү өчен әһәмиятле. Татар язма әдәби теленең диалекталь нигезе, күпчелек галимнәр билгеләвенчә, Идел буенда формалашкан. Башка төрки язма истәлекләрдәге кебек үк, бу язмаларда да грамматик формалар катнаш хәлдә кулланыла. Борынгы төрки, караханлы-уйгыр әдәби теле өчен хас традицион формалар белән бергә, шул чор гомумхалык сөйләм теле өчен хас күрсәткечләр теркәлгән. Тикшерүдә статистик алым куллану сүз төркемнәренә хас грамматик категорияләрнең кулланылышын җентекле күзәтергә, әсәр текстында грамматик формаларга хас нормаларны билгеләргә, норма вариантлылыгын ачыкларга мөмкинлек бирә.

## 1.1. Исем

Исем сүз төркеменә хас сан, тартым, хәбәрлек, килеш грамматик категорияләре болгар чорында язылган текстларда ук кулланылышта булуы күренә. Шуның белән бергә, әлеге сүз төркеменең һәр категориясендә үз чоры өчен хас үзенчәлекләрнең дә чагылыш табуын күрәбез.

**Сан категориясе.** Грамматик категория буларак, сан исемдә предметның бер яки бердән артык булуын, билгесез күплеген белдерә. Берлек санның аерым күрсәткече юк. *-лар/-ләр* кушымчасы – гомумтөрки форма, һәм ул тел тарихы буенча хезмәтләрдә борынгы нигез телдән үк килә торган архетип буларак билгеләнә. Күплек сан күрсәткече буларак *lar (*-лар*) кушымчасы, чуаш теленнән кала, хәзерге барлык төрки телләрдә кулланыла [Кормушин, 2008, с. 183]. Берлек сан кушымчасыз, нуль формада килә, һәм ул сүзнең нигезе белән тәңгәл килә. Берлек сандагы исем предметларның берлеген, ягъни бер данәдә булуын күрсәтә. Сан категориясең бу мәгънәсе грамматик планда, ягъни парадигматикада чагылыш таба.

«Кыссаи Йосыф»тан мисаллар:

а) берлек сандагы исем предметларның реаль берлеген белдерә. Мисалларга игътибар итик: Андан соңра аның дусты (دوستی) Мөхәммәд (محمده) [А.1а]; бән әшитдим, изгү тәэвил (تاوویل) қылды имди [С.Б. 3б–33]; җөмләсинең хатеринә (خاطرین) ғоссә (غص) йағды [С.Б. 3б–34].

«Ана вә угыл» дастанынан мисаллар: Ул хатунның халәли өлмеш иди [Н. 59.14]; уғланны остазға вирмеш ирди [Н. 59.15]; анасының сағ көзи шул дәм чықар [Н. 61.67]; намаз (نامز) уақыты болды уғлан турмады [Н. 60.31] һ.б.

ә) төп үзенчәлекләре ягыннан хосусый затларны, предмет һәм күренешләрне белдергән исемнәр берлек санда була: ғәзиз Йосыф (یوسف) тәмам он бир йәшәр ирди [С.Б. 2а]; Йосыфи (یوسف) без қатумыза үндәйәлүм [С.Б. 4а]; үндәйүбән Йосыфи (یوسف) кәлтүрдиләр [С.Б. 4а]; Йосыф дүшин (دوشن) анлара әйтү вирмәз [С.Б. 4а] һ.б. «Ана вә угыл» дастаны текстыннан мисаллар: вар иди Кәғбә шәһәриндә бир хатун (خاتون) [Н59.1]; хәбәр улды Мостафа Мөхәммәдә [Н. 61.77]; чүнки инде Җабраил көкдән йерә Мостафайа хак сәламен тикерә [Н. 65.227.228] һ.б.

б) сан белән ачыкланган исемнәр шулай ук берлек сан формасында килә: йүз биң ирдән (ایردن) артық ирди аның фазле (فضل) [У.И. 46]; түрт биң түрт йүз мәсҗед (مسجد) бина (بنا ) қылмыш имди [У.И. 46]; дуғар күн, тулун ай, он бир йулдуз (اولدوز) [С.Б. 2б]; ай, күн, он бир

йулдыз (یولدوز) аңа сәҗдә кылмыш [С.Б. 3б]; он кәрендәш (قرنداش) йыглашуб утурдылар [С.Б. 4] һ.б.

«Ана вә угыл»дастаны текстыннан мисаллар: кырык рузә тутам йимәйем [Н. 60.61]; Мостафа артынча түрт йары илә [Н. 62.110] һ.б.

Исемнең күплек формасы *-лар/-ләр* кушымчасы белән барлыкка килә. Аның төп грамматик мәгънәсе – предмет һәм күренешләрнең бердән артык булуын, билгесез күплеген белдерү. «Кыссаи Йосыф»тан мисаллар: андан соңра ул бәхтиар ирәнләрә (ایرانلره), хак хәбибе Мостаф аны күрәнләрә (کورانلره), һич эксәксиз утуз үч мең ирәнләрә (ایرانلره) [У.И. 3]; гакил коллар хатерини байытмага бәнем бу арысланларым [Ф. 68.3]; һиләлә биңзәр сәнең кашлареӊ вар, йенҗүйә биңзәр сәнең дешләрең вар, гәҗәб зиба мишек йопар сачларың вар [Ф. 162.1–3] һ.б.

«Ана вә угыл» дастаныннан алынган мисалларга игътибар итик: агызлары (اغزلار) илә канатлары (قاناطلار) илә су алдылар [14А.216]; газиларның (عازیلارننک) күккә чыкар фөрйады [11Б.137] һ.б.

Төрле табигать күренешен белдергән яки үсемлекләр дөньясына караган, матдәлекне белдергән исемнәргә ялганганда, *-лар/-ләр* кушымчасы бүленмәгән күплекне, әйберләрнең төрле төрләрен белдерәләр: «Кыссаи Йосыф»: әлуан йәрләр (یرلار), акар сулар (سولار) җөмлә күрсүн, сәхраләрдә (صاحرلاردا) раузәләрдә (روضلاردًا) сачәки дирсүн [С.Б. 4б.48]; йиремездә игенләри һич уңмады [Ф. 220.3] һ.б.

Абстракт мәгънәле исемнәргә *-лар* кушымчасы конкретлык өсти: кәрдәшләрим, өмидләрим, нәтә буйлә кылурсыз, гәзизләрим [Ф. 64.1–2]; кәрдәшләри аны ишдеб кәйед кылды, хәсәдләри, кәйедләри галиб улды [Ф. 54. 21–22]; җөмләңез игү тимарлар кыласыз [Ф. 60.39]; анлар сәни сатдылар кәм йармакга, диләкләри байык сәндән айрылмакга [Ф. 98.34] диләкләри, морадлары шөйлә улды [Ф. 98.43] һ.б.

Ялгызлык исемнәргә, туганлык атамаларына ялганып килгән *-лар* кушымчасы гомумиләштерүне белдерә: кәнганиләр кәлсүн [Ф. 226.16]; аналардан сәнең кеби дугмаз имди [Ф. 162.28] һ.б.

Текстта, бигрәк тә, Йосыфның туганнарына мөрәҗәгате синоним сүзләрдә *-лар/-ләр* күплек кушымчасы белән бирелгән (28 мисал очрады): улуларым бирлә анда буйлә варсам [Ф. 58.22]; агаларым, бәңа рәхим кылың [Ф. 64.30]; кәсд кылдылар бәгерләрим, куткаргыл сән [Ф. 64.38]; Йосыф әйдер улуларым, бән күлдегүм [Ф. 66.41] һ.б.

Текстларда сан белән ачыкланган исемнәрнең күплек кушымчасы белән килү очраклары теркәлгән. Моның кулланылыш авторлар

тарафыннан стилистик максатта – дәвамлылыкны көчәйтү чарасы буларак кулланылган: йитмеш йыллар йығлайубән бу күн булдым [Ф. 246.23]; йөз мең йекерме түрт мең нәбиләр уғланга шәфәғәт итмәдиләр [Н. 6.102-103].

Исемнәрнең күплек формасы экспрессив максатта кулланыла: һәр заманда күкләр таба нәзар қылса, күк йүзендә йулдызлары күрәр исә [Ф. 148.9-10]; йаулақ улу бәшарәтләр улур имди тәүбә қылыб, зарилықлар қылур имди [Ф. 116.16] һ.б. «Ана вә угыл» дастаны: ул солтанлар (سلطانلار) солтаны қадыйр иши [С.Б. 14].

Гарәп-фарсы алынмаларына күплек кушымчасы ялгана: дәрмандәләр дәстгире мәли рәхман фазлы бирлә Җәбраилә қылды фәрман [Ф. 76.1]; андан соңра шиддәтләрдән бән қортарам [Ф. 77.10]; хәсудләри хезмәтинә кэлдәчидүр [Ф. 77.13]; аны күреб, нәүхәләри битәр улды [Ф. 82.13] һ.б.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, тикшерелгән чыганакларда берлек сан традицион тәртиптә кушымчасыз килә, ә күплек сан бары тик *-лар/-ләр* кушымчасы белән генә кулланыла. Мәгънәләренә килгәндә, *-лар/-ләр* санала торган предмет һәм күренешләрне белдергән исемнәрдәге күплек кушымчасы предметларның бердән артык булуын, аның билгесез күплеген, төрле табигать күренешен белдергән яки үсемлекләр дөньясына караган сүзләр шулай ук матдәлекне белдергән исемнәргә якын торалар, бүленмәгән күплекне белдерәләр.

**Тартым категориясе.** Исемдә бер үк вакытта предметны һәм аның иясен, ягъни предметның кайсы затныкы икәнлеген белдерә торган үзенчәлекле сүз формасы, ягъни тартым категориясе – бөтен төрки телләр өчен уртак һәм бик борынгыдан килгән грамматик категория. Әдәби тел тарихы фәнендә аерым сүз формаларының тарихи ягын өйрәнү әһәмиятле бурычлардан санала. Бу уңайдан исемдә тартым кушымчаларының, аерым алганда I, II зат тартым кушымчаларының килеп чыгышы тартым кушымчаларының иялек килешендәге зат алмашлыкларына бәйле карала.

Болгар чоры әдәби телендә тартым белән төрләнеш, тартым кушымчалары, гадәттә, борынгы төрки нигез телдәгечә үзгәрешсез саклана.

«Кыссаи Йосыф» поэмасында Йосыф язмышындагы төрле вакыйгаларга бәйле үзенең туганнарына, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итә, шуңа бәйле әсәрдә I зат тартымлы исемнәрнең *-ум/-үм, -ым/-им* кушымчалы берлек формасы еш кулланылган: уғлум (اوغلوم), инанғыл

байық бәңа [С.Б.3а]; иләhем (الاهيم) рәхманемғә (رحمانمغه) сығынмайынму [У.И. 1б]; ғомрим аның үзрә кэчсүн имди [Ф. 82.36]; ғүрем ичрә җаным мәҗрух қылдың имди [Ф. 104.8]; кәлә бирлә қомашым атласым чуқ [Ф. 96.6] h.б.

Иренләшү гармониясенең саклануы буенча кушымчаларның язылышы традицион әдәби тел нормаларына якын, күпчелек *-ум/-үм* формасында теркәлгән, шулай ук вариатив язылыш та урын ала. Чагыштыр: дүшүм (5 тапкыр): дүшүм ичрә ағлайу үрә дордым [Ф. 62.32]; дүшүм ичрә бир зиба сурәт көрдүм [Ф. 130.6] h.б.

Әсәрдә I зат тартымлы исемнәрнең күплеге борынгы төрки әдәби телдән килгән *-мыз/-миз* традицион формада очрый, берлек сан белән чагыштырганда, кулланышы шактый чикләнгән: атамыз (اتامز) қашында без қалалум, hәмишә сәүклү биз улалум, Атамыза (اتامزه) игү тимар биз қылалум, [С.Б. 4б]; атамыз (اتامز) аны биздән артуқ сәүәр [С.Б. 4б]; бизим уқларымыз алгалы вардық иди [Ф. 82.23] h.б.

«Ана вә угыл» дастанында исемнәрнең тартым белән төрләнүе Кол Гали әсәре теленнән аерылмый: I зат берлек hәм күплек сан: күрдүм анам сәни түшүмдәҗанумны (جانومنى) утқа йакарсән бәни [9Б.38], бире кәлгел ахыр көргел хәлеми (حالمى) [11Б.144] h.б. Тартым кушымчасы ана, угыл туганлык атамаларына ялганганда, аерым бер иркәләү, яратуны белдергән, истәлек телендә эндәшү сүзе буларак кулланылган: анасы әйтүр әй уғлум көзим нуры ... Тәңри рәхмәт әйләсен қузым сәңа [Н. 60.33, 36]; кил рәхим қыл җаным анам бәңа [Н. 63.147] h.б.

б) II зат берлек санда *-ең/-ың,* күплек санда *-ңыз/-ңез* кушымчалары ала: хәмдү сәна тәлим айғыл сөбханеңа (سبحانيڭا) [С.Б.3а]; җәмалең қуйаш кеби ғишқың қаты [Ф. 160.42]; батилдән нәфсең манығ улғыл диди [Ф. 166.6]; фиғелең хуш ғишкың йаулак датлу дурур [Ф. 160.19]; атаң Йагқуб бу әхуале белмәдимү [Ф. 104.9]; сәнен атаң Йагқубдур бабаң Исхақ [Ф. 104.13] h.б.

II зат күплектәге тартым кушымчасы сирәк, барлыгы сигез мисалда очрый, традицион әдәби телгә хас *-ыңыз/-иңиз* вариантында кулланыла: Қәрдәшеңез (قردشڭز) Йосыф дәйүр бир дүш күрмеш, атаңыз (اتاڭيز) Йағқуб аны изгү йурмыш [С.Б. 3б–33]; нәүбәтләшү игнеңезгә күтәрәсиз (60:38); ул зәғифә қәрдәшеңез йарлы Динә [Ф. 246:10]; атаңыз Йағқуб аны изгү йурмыш [Ф. 54:19]; кәрдәшеңезканыны күтәрмәң дир [Ф. 70:26].

«Ана вә угыл» дастаны: II зат берлек сан: абдәст алуб, намазыңа (كانامازون) бар сана [9Б-35], бойорығың (بيورغنك) бирлә қылмышлар ха-

зир (41А-221) һ.б. «Ана вә угыл»дастанында II зат тартым белән төрләнгән исемнәр берлек сан формасында гына кулланыла

III зат берлек санда – *-ы/-и, -сы/-си,* III зат күплектә *-лары/-ләри* кушымчалары алалар. III зат берлек санның мәгънәсе киң, ул сөйләмдә катнашмаган башка бер затка гына түгел, күп төрле әйберләргә ишарәли; аның ғишкы буйлә қылды бәни имди [Ф. 152.16]; вар иди Йағқубың бир үгәй қызы (قزى) [С.Б.3б-32]; Йосыф дүшин (دوشن) анларә әйтү вирмәз [С.Б.4а-38] һ.б.

III зат берлектәге *-сы/-си* кушымчасы сузыкка тәмамланган нигезгә ялгана: нәфси ары күңли шадекәм улсун имди [Ф. 60.4]; буның улу дәдәси мәғруф хәлил [Ф. 70.5]; дәдәси Исхак сәүчи дин табибе [Ф. 50.15]; ул Заһиднең доғасы қабул улды [Ф. 72.18] һ.б.

III зат күплектәге тартым мәгънәсен белдергән *-лары/-ләри* текстта шулай ук чикле кулланылган: қәрдәшләри (قردشلارى) аны ишдеб кәйед қылды, Хәсәдләри, кәйедләри ғалиб улды [С.Б. 3б]; қәрдәшләри (قردشلارى) хатерин қуйумади [С.Б. 4а]; аталары күзүндин ғаиб улдылар [Ф. 62.9]; хәсрәтләри бир биринә қаушдырам (Ф168:43); диләкләри морадлары шөйлә улды [Ф. 98.43].

«Ана вә угыл» дастанында: III зат берлек һәм күплек сан: уғланчығың хәлинә (حالين) кем бағасыз [13А.187], ағызлары (اعزلارى) илә, қанатлары (قاناطلارى) илә су алдым [8А.217] һ.б._

Тикшерүләрдән күренгәнчә, ике әсәр текстында да тартым категориясе өч затта һәм санда теркәлгән. Идел буе Болгар чоры әдәби телендә тартым белән төрләнеш, тартым кушымчалары нигездә, борынгы төрки нигез телдәгечә үзгәрешсез саклана. Тартым кушымчалары рәт гармониясенә бәйле рәвештә һәм төрләнә торган нигезнең сузыкка яки тартыкка бетүенә карап, вариантлашалар.

| | Берлектә | Күплектә |
|---|---|---|
| I зат | -ум/-үм, -ем/-им | -мыз/-мез |
| II зат | -ың/-иң | -ыңыз/-иңиз |
| III зат | -ы/-и; -сы/-си | -лары/-ләри |

**Килеш категориясе.** Килешләр белән төрләнү төрки телләрдә бик борынгыдан килгән грамматик категория булуга карамастан, хәзерге төрки телләрдә исемнең килешләр белән төрләнешендә аермалыклар зур түгел. Барлык төрки телләр өчен диярлек, мәсәлән, алты килештән торган төрләнеш парадигмасы хас, һәм андагы килешләрнең һәркайсы

борынгы нигез телдән үк килә, ягъни борынгы нигез телгә реконструкцияләнә [Благова, 1982, с. 290; СИГТЯ, 1988, с. 140]. Идел буе Болгар дәүләте чорында язылган истәлекләр телендә төрле килеш формаларының кулланылыш чагыштырмасын һәм шулай ук килеш формалары белдергән грамматик мәгънәләрне өйрәнү ике төрле төрләнеш тибын күрсәтә: а) тартымсыз төрләнеш; ә) тартымлы төрләнеш. Тартымсыз төрләнештә килеш кушымчалары турыдан-туры сүз нигезенә ялгана. Тартымлы төрләнештә исә килеш кушымчалары тартым кушымчаларыннан соң ялгана. Шуңа бәйле рәвештә тел тарихы фәнендә һәр ике төрләнештәге структур үзенчәлекләр һәм аларның формалашу тарихы аерып карала. Тартымсыз төрләнештә килешләр белән төрләнешнең ике структур тибы урын ала: а) угыз төрләнеше; ә) кыпчак төрләнеше.

Асылда төньяк төрләнеш (кыпчак) тибына караган түбәндәге кушымчалар теркәлгән:

| Килеш | Кушымча |
|---|---|
| Баш килеш | нуль форма |
| Иялек килеше | -ның/-нең |
| Юнәлеш килеше | -га/-гә, -ка/-кә |
| Төшем килеше | -ны/-не |
| Чыгыш килеше | -дан/-дән, -тан/-тән |
| Урын-вакыт килеше | -да/-дә, -та/-тә |

Тартымсыз исемнәргә бу төрләнештә, сузыкка яки тартыкка тәмамлануына бәйсез рәвештә, һәрчак тартык авазга башланган кушымчалар ялгана.

Көньяк (угыз) тибына караган төрләнештә өч килештә, ягъни иялек, төшем, юнәлеш килешләрендә килгән һәм тартык авазга тәмамланган исемнәргә сузык авазга башланган, яисә сузык аваздан торган кушымчалар ялгана:

Иялек килеше: *-ың/-иң, -уң/-үң*

Юнәлеш килеше: *-а/-ә*

Төшем килеше: *-ы/-и*

Килеш кушымчаларындагы әлеге үзенчәлек бу телләрдә I, II затта тартымлы төрләнештә дә чагылыш таба.

Традицион әдәби телгә хас уйгыр тибы исемнәрнең тартымлы төрләнешендә сакланган:

Юнәлеш килеше: *-ыйга/-игә*

Чыгыш килеше: *-дыйн/-дин*

Уйгыр төрләнешендә III зат тартымлы исемнәрдә, тартымсыз исемнәрдәге кебек үк, барлык килеш кушымчалары тартык авазга башлана. Карлык төрләнешендә исә III зат тартымлы исемнәрдә килеш кушымчалары турыдан-туры тартым кушымчаларыннан соң ялгана, ягъни башка төрләнешләрдә урын алган *-н* элементы бу төрләнештә чагылыш тапмый.

Өйрәнелә торган чорда аерым килеш кушымчаларында күзәтелгән грамматик форма, грамматик мәгънә үзенчәлекләре татар телендә килешләр системасының үсеш-үзгәреш закончалыкларын ачыкларга мөмкинлек бирә.

*Баш килеш.* «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә баш килеш нуль форма белән бирелә. Бу барлык төрки телләр өчен дә хас. Төрки телләрдә баш килеш үзенчәлекле грамматик килеш буларак карала, чөнки аның синтаксик функцияләре һинд-европа телләрендәге баш килешнекенә караганда күпкә киңрәк. Фәнни әдәбиятта бу килешнең төрлечә аталуына да аның бу үзенчәлеге тәэсир иткән.

Баш килеш истәлекләр телендә аеруча киң кулланылыш таба һәм түбәндәге функцияләрдә теркәлгән:

а) субъект мөнәсәбәтен белдерә:

«Кыссаи Йосыф»тан мисаллар: шәйтан (شيطان) душман (دوشمان) улур имди [С.Б. 3б]; мөлкәт эчрә билә шәрик ул әхәдә (احادا) [С.Б. 1а]; қәрдәшеңез Йосыф (يوسف) бир дүш күпме (كورمش), Йосыф (يوسف) дүшин анлара әйтү вирмәз [С.Б. 4а–38]; ул чыбықлар җөмләси алтун улсун [Ф. 54.30]; [Ф. 66.25]; һәр биринең башында алтун таҗлар [Ф. 132:18]; ғишқы йиңде асла сабыры қалмаз имди [Ф. 146.44] һ.б.

«Ана вә угыл» дастаны мисалында: хәзрәти Илйас (حضراتى) кәлүр ирди катына» [8Б.9],ул оғлан (اوعلان) Кор’әнгә кермеш иди [9А.23], көзләри йәш (ياش) толды хатун ағлады [13А.194]; утыз үч миң сахәбә (صحابا) қылды [13Б.206];

ә) туры объект функциясен үти («Кыссаи Йосыф» мисалында): Сөбханемдән мәдәд-йари (مادد- ياري) тиләйенмү [С.Б. 1б–12]; халиқ ана узун ғомер рузи қылды [Ф. 72.19]; бу уғланның ағырынча алтун виргел [Ф. 140.26]; ики қызыл алтун қуйғыл бир йүнемдә [Ф. 88.19] һ.б.

«Ана вә угыл» дастаны: Ғали чағырды утун (اوتون) кәлтүдиләр [Н. 63.134]; үтмәк алғыл анда баруб йийәсән [Н. 60.57]; пычақ алды

кәндүзүн ормаға [Н. 61.73]; ағызларыла қанатлары илә су алдылар [Н. 65.217] һ.б.

б) I һәм II төр изафә мөнәсәбәтендә тора: атаңыз Йағқуб (اتانکز یقوب) аны изгү йурмыш [С.Б. 3б–33]; адәм уғлы илә бир пәри улур имеш [Ф. 110.37]; Рахилә уғлы Йусефи күрәрмүсез [Ф. 56.15];

«Ана вә угыл» дастаны: татлу уйку вирмеш иди аллаһ аңа [Н. 59.30]; әбдәст алуб намазыңа бар сана [Н. 60.35]; йығладылар ики-си йаш сачдылар [Н. 64.183];

в) баш килештәге исемнәрнең хәбәр булып килү очраклары теркәлгән.

«Ана вә угыл» дастаны: зирә уғлан йарымыз қәрендәшемез [12Б.172]; ул солтанлар (سلطانلار) солтаны қадыйр иши [14А.213].

Баш килешнең каберташ язмаларында күп функцияле булуы теркәлгән: а) субъект: Täŋri rähmäte berlä sewendürsün; ә) объект: mäsʒlär gïjmarät qïlqan; б) изафә сүзтезмәдә аергыч: köηellär özäge [Хакимзянов, 1987, б. 48].

*Иялек килеше.* Иялек килешендәге исем җөмләдә икенче исемне ачыклый, аның грамматик мәгънәсе – иялек мөнәсәбәтен билгелелек төсмере белән белдерү. «Кыссаи Йосыф» поэмасында һәм «Ана вә угыл» дастаны текстларында иялек килешенең төньяк һәм көньяк төрләнешенә хас ике варианты да урын алган: хәзерге татар әдәби теле өчен хас булган *-ның/-нің* һәм угыз телләренә хас *-ың/-иң* формалары. Әсәр телендә кушымчаларның кулланыш нормасын билгеләү өчен үткәрелгән статистик исәпләүләр түбәндәге нәтиҗәләрне бирде: «Кыссаи Йосыф» әсәрендә исемнәрнең төрләнеш парадигмасында 47 сүзформа – *-ның/-нің* формасында, ә 29 *-ың/-иң* кушымчаларын алып төрләнүе теркәлгән. Алмашлык сүз төркемнәрендәге төрләнешне чагыштырып карасак, саннар түбәндәгечә:

*-ның/-нің* кушымчалы 28 сүзформа, *-ың/-иң* белән 9 очрак теркәлгән. Исем фигыль функциясендәге сыйфат фигыльләр бары *-ың, -иң* аффикслары белән кулланылган (барлыгы 4 очрак). Барлыгы истәлектә *-ның* варианты 75 мәртәбә кабатлана, угыз телләре өчен хас *-ың* формасы 42 сүздә теркәлгән. Димәк, әсәр телендә шул чор Идел буе халык сөйләм теленә хас кыпчак формасы күпчелекне тәшкил итә. Мисаллар:

а) *-ның/-нің:* Бу сүзә Йәһүдәнең (یهودهننک) җаны күйди [У.И. 14]; варыб Ғаднең қойусына киргил [С.Б. 9а.72], Анасының синендән бир үн кәлди [Ф. 104.1]; Гад қойусының башыға тәкүрдиләр [Ф. 74.18];

қолларының җөмләсендән ул һәйбәтлү [Ф. 102.18]; қолумызның үч дөрлү ғәйбе вардыр [Ф. 94.46] һ.б.

ә) *-ың/-иң:* Йосыфең (يوسفنک) нуры бирлә қойу тулды [С.Б.9а]; Гәзизең бу сәрайда нә эши вар [Ф. 160.14]; Хәлилуллаһ Ибраһимең уғлы имди [Ф. 50.16]; 3): аны ишдүб Йағқубың ғаклы шашды [Ф. 82.9] һ.б.

«Ана вә угыл» текстында иялек килешле сүзформалар шулай ук актив кулланылган, иялек килешенең бары тик кыпчак төрләнеш тибы *(-ның/-ниң, -нуң/-нүң)* гына теркәлгән. Мисаллар: ул хатунның (خاتوننک) халәли өлмеш иди [9А.13], ул отнуң уртасыга йағдурдылар [Н. 65.218] һ.б.

Эпитафик язмаларда иялек килешенең кыпчак төрләнеш тибы – *-ның/-ниң* очрый, күбесенчә ай атамаларында кулланылган: šäwwal ajïnïïŋ...küne [Хакимзянов, 1987, с. 48].

Болгар чоры язма ядкәрләр телендә иялек килешенең кыпчак төрләнеш тибы норма булып тора, вариатив угыз күрсәткече «Кыссаи Йосыф» текстында гына теркәлгән.

*Юнәлеш килеше.* Тикшерелә торган истәлекләр текстында юнәлеш килешенең *-а/-ә, -йа/-йә, -ға/-гә, -қа/-кә* күрсәткечләре теркәлгән:

«Кыссаи Йосыф» поэмасында юнәлеш килешенең көньяк төрләнешкә хас: а) *-а/-ә, -йа/-йә* формасы 200 сүзформада (шулардан 148 е – исем, 48 е – алмашлык); ә) *-ға/-гә* варианты 52 мәртәбә (47 исем, 5 алмашлык) кабатлана. «Ана вә угыл» дастанында тартымсыз төрләнештә кыпчак теле өчен хас күрсәткечләр: *-ға/-гә, -қа/-кә* норма булуы ачыкланды, 28 сүздә теркәлгән, угыз төрләнешенә хас *-а/-ә, -йа/-йә* 18 тапкыр теркәлгән. Мисаллар:

а) *-а/-ә*, *-йа/-йә* вариантлары исемнең соңгы авазы нинди булуга бәйле ялгана: бу әхуалә ул дөшүрди байық бәни [Ф. 152.1]; судагы балықлара ул бойурды [Ф. 116.38]; Ибраһим гәммамәсин баша чалды [Ф. 60.29]; қәрдәшләрим аз бәһайә сатмасәйди [Ф. 96.10]; бондан уңдан көзгүйә баңдуңмыды [Ф. 146.9; 92.5] һ.б. «Ана вә угыл» дастанында: уғлан йүзи биңзәр ирди күнәшә [Н. 62.104]; күнәшә ухшар иди аның йүзи [Н59.17]; күреклү йүзи бәңзәр ирди күнәшә [Н. 59.20];

ә) «Кыссаи Йосыф» поэмасында башлыча *-ға/-гә* кушымчалары килә, ассимиляция язуда чагылмаган. Мисаллар: кәлүбән бу әлуангә нәзар кылсун [Ф. 156.14]; ул балыкға ики угыл рузи қылды [Ф. 118.31]; йирдән күкгә нурдан дрәк улур имди [Ф. 118.44; 76.32] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында *-ға/-гә, -қа/-кә* кыпчак күрсәткечләре норма булып тора: дөнйасын ахирәткә сатмыш иди [Н. 59.3]; җанумны отқа йақарсән [Н. 60.38]; кәлди хатун қатына нурга бата [Н. 61.80] һ.б.

Текстта вариатив төрләнеш очраклары теркәлгән: мән мәскинне отқа быракдылар [Н. 63.149]; канқи ғаурәт оғланын отқа йақар [Н. 64. 202] ~ күтәрди кәндүзене атды удә [Н. 64.204] һ.б.

Семантикасы буенча юнәлеш килеше һәр очракта дияргә була, исемне фигыльгә ияртә һәм урын, вакыт, максат, объект мөнәсәбәтләрен белдереп килә.

Тартымлы исемнәрнең юнәлеш килешендә төрләнеш үзенчәлеге. Тартымлы төрләнештә килеш кушымчаларында тартымсыз төрләнештәге система беркадәр үзгәрә, һәм бу очракта төрле затта килгән исемнәргә кыпчак, угыз, карлук-уйгыр төрләнеше өчен хас кушымчалар ялгана.

I һәм II зат тартымлы исемнәргә юнәлеш килешендә норма буларак сузык аваздан торган *-а/-ә* кушымчасы ялгана.

I зат тартымлы исем берлек санда: дидаремә җанын фида қылур имди [Ф. 114.36]; бу дүшүмә күреклү тәэвил қыйлу виргил [Ф. 52.11]; бәнем датлу җанемә туйдыңызму [Ф. 66.15]; Фирқәт отын җаныма қуйырдылар [Ф. 102:30]; ғөрбәт тунын игнемә кийүрдиләр [Ф. 102.31].

I зат тартымлы исем күплек санда. Мәсәлән: атамыза (اتامزه) – (10 сүздә теркәлгән): атамыза әхуал нәтәк белдерәсиз [Ф. 66.19]; қатумыза (قتومزه): Йүсефи без қатумыза үндәйәлүм [Ф. 54.29] һ.б.

Кыпчак төрләнешенә хас *-ға/-гә* варианты өч сүздә урын алган: бу кичә куйнымда бәгримгә қысайын [Ф. 58.42]; күңелүмгә фикрү фәһем сувы виргил [Ф. 48.3]; соңра дүнеб атамызға тәүбә қылам [Ф. 60.13]

II зат тартымлы исем берлек санда *-а/-ә* кушымчалы варианты гына теркәлгән: азад қылыб атаңа илтә идүм [Ф. 142.31]; бир шәриф қол элеңә керәр имди [Ф. 88.24]; бән сәнең әмереңә мотиғ улам [Ф. 154.6]; қәрдәшләриңә қушуб изәйен [Ф. 58:41]; күрүбән һәм йүзләриңә ғашиқ улдым [Ф. 76:42].

«Ана вә угыл»: күр нә кәлди аһ бәнем башыма (باشما) [Н. 63.152]; абдәст алуб, намазыңа (نامازون كا) бар сана [Н. 59.35]; морадыңа, мақсудыңа ирмәгел [Н. 62.105] һ.б.

II зат тартымлы исемнең күплек санда *-гә* варианты теркәлгән: нәүбәтләшү игнеңезгә кутәрәсиз [Ф. 60.38].

III зат тартымлы төрләнештә берлек һәм күплек саннарда өстәмә тартык н авазы өстәлә *-а/-ә* кушымчасы ялгана. Мисаллар:

«Кыссаи Йосыф» поэмасында: итәкенен алтына сығындырды [Ф. 68.27]; арқасына басубән бенәр имди [Ф. 118.4]; Зөләйхә бу кәүлейә рази улды [Ф. 130.29]; андан кичди Кодес шәһренә анлар кирди [Ф. 110.21] һ.б.

III зат тартымлы исемнәргә *-ға/-гә* кушымчалары турыдан-туры тартым кушымчаларыннан соң ялганып, башка төрләнешләрдә урын алган *-н-* элементы чагылыш тапмый, борынгы төрки әдәби телгә хас карлук төрләнеше әсәр телендә еш кулланылган: йәнә Йәһүдә аҙақыға ағнады [Ф. 64.46]; Йағқуб сәүчи алдыға кәлтүрдиләр [Ф. 82.42]; аҙақларыға ағнайу чуқ йалуарды [Ф. 64.31]; нәүбәтләшү игенләригә күтәрди [Ф. 60.47] һ.б.

*-н-гә* кушымчасы ялганган очрак сирәк теркәлгән: Шәмғун йәмә йүзингә бир йаңақлады [Ф. 64.43]; Шәмғун йүзингә тилмерүб зари қылды [Ф. 64.42] һ.б.;

«Ана вә угыл» дастанында III зат тартымлы исемнәрдә *-ына/-инә* кушымчалы сүзформалар күпчелекне тәшкил итә, 20 сүзформада теркәлгән, *-ыға* күрсәткече дүрт мисалда күзәтелде. Мисаллар: а) *-ына:* хәзрәти Илйас кәлүр ирди қатына (قاتينا) [Н. 64.204]; түшти уғлан анасы айағына [Н61.89]; ғазилар йабыштылар буйнына әлинә [Н. 61.88]; атды уғлан аташы анасы йүзинә кодрәт илә туқунды сағ көзинә [Н. 61.65–66] һ.б.

*-ыға* кушымчасы дүрт сүзформада теркәлгән: ул отның уртасыға (اورتاسينا) йатқурдылар [Н. 63.139]; чықдум күрдүм ан аның көзигә қан булашмыш ул ай йүзигә [Н. 59.51–52]; ул отның уртасыға йағдурдылар [Н. 65.218]. *-нға* кушымчасы ялганган очрак сирәк теркәлгән: Мостафаның аҙақынға (اذاقيغا) дүшдиләр [12А.169].

Кабер ташы язмаларында юнәлеш килешенең кыпчак төрләнешенә хас *-ка, -га* кушымчалары очрый: baqïj dönjaγa; hiǯrätqa [Хакимзянов, 1987, с. 50].

*-ра/-рә; -гару/-гәрү* кушымчалы юнәлеш килеше формаларының актив кулланылышы шулай ук, нигездә, Орхон-Енисей язмалары һәм борынгы уйгыр язма истәлекләре өчен хас. «Кыйсса-и Йосыф» поэмасында һәм «Ана вә угыл»дастанында *тышра*, *эчрә*, *үзрә* кебек аерым сүзләрдә кабатланып кулланыла.

«Кыссаи Йосыф» поэмасында *тышра* (5 тапкыр теркәлгән): гәзиз Йосыф ул дәмдә чықды тышра [Ф. 92.18]; сәрай ичрә алтун көрси хазир қылды [Ф. 122.39]; йәнә зиндан ичрә салындачи [Ф. 78.11] һ.б.

*Үзрә* (27 мәртәбә теркәлгән): аның үзрә тәлим дөруд улсун имди [Ф. 46.8]; аның хөкме қоллар үзрә лаиқ дорыр [Ф. 126.2]; Йусеф кәлеб ул таш үзрә ултурыр имди [Ф. 76.20]; Зөләйха Йусеф үзрә йүрүр имди [Ф. 166.12] һ.б.

«Ана вә угыл»дастанында *тышра* сүзе теркәлгән: тышра чықды күрди оғланының хәлин [Н. 64.191].

*Төшем килеше.* Төшем килешенең текстларда тартымсыз төрләнештә кыпчак һәм угыз вариантлары: *-ны/-ни, -ы/-и* ялганып, исемне фигыльгә ияртә. «Кыссаи Йосыф» истәлегендә *-ны/-ни* формасы 79 мәртәбә, ә угыз төрләнешенә хас *-ы/-и* 64 мәртәбә кабатлана. «Ана вә угыл» дастанында шулай ук кыпчак төрләнеше күпчелекне тәшкил итә (13 очрак), *-ы/-и* очрагына 5 сүзформа теркәлгән. Текстта төшем килеше, башлыча, туры обьект мәгънәсендә килә, сирәгрәк вакыт мөнәсәбәтен белдерә. Мисаллар:

«Кыссаи Йосыф»та:

а) *-ны/-ни:* ул әгзаны бәңа алуб кәлең имди [Ф. 82.32]; бу әсрарни зинһар сакла дәйүр имди [Ф. 152.12]; қәрендәш қәрендәшни һич үлдермәз [Ф. 68.38]; хәқыйкәтдә бу қолны мән һәм алурмән [Ф. 96.2] һ.б.

ә) *-ы/-и:* әманәтдер бу әсрари сақла имди [Ф. 144.12]; бу әсрари бәйан қылсаң билсәм имди [Ф. 144.4]; сабыр бирлә ишләгел ушбу иши [Ф. 132.1]; ул қолы учуз сатун алдачисән [Ф. 88.25] һ.б.

Бер җөмләдә вариатив кулланылып килгән очраклар теркәлгән: падишаһ хәлемез дишвар улды бези дут, Ибне Йәбинне қуйғыл имди [Ф. 262.24] .

«Ана вә угыл»дастаныннан мисаллар:

а) *-ны/-ни:* дөнйа бирип ахирәтни (اخيرتنى) алды сатун [Н. 59.2]; нәфсени (نفسنى) өлтүрмәгә қадир иди [Н. 59.11]; уғлан тәмам Кор’анни (قراننى) оқымыш иди [Н. 59.24); җүмлә ғаләмни (عالمنى) отқа йандурмағыл [Н. 62.114]; йүземни чәүереп мән пәйгамбәрә [Н. 60.40]; җанумны отқа йакарсән [Н. 62.38]; Мостафа ул хатунны билүр иди [Н. 61.81]; отунны имди хәзер әйләделәр [Н. 62.128] һ.б.

ә) *-ы/-и:* уғлан әйтүр ана көргел халими үлтererләр кисәрләр әлеми [Н. 61.90-91]; Хақ белүр кем қайғулары йийәсен [Н. 62.121]; бире килгел ахыр күргел хәлеми қуртар имди ошбу отдан җанымы [Н. 63.44–45] һ.б.

Тартымлы төрләнеш. I заттагы тартымлы исемнәрдә төшем килешенең *-ны, -и* варианты кулланыла: Бән қызымны хәқыйкәт сәңа вирәм [Ф. 132.37]; қолумызы сатмаға рәуа күрдек [Ф. 98.14]; қолумызы сәңа тәслим қылдық имди [98.16] һ.б.

II заттагы тартымлы исемнәрдә төньяк һәм көньяк төрләнешкә караган формалар катнаш хәлдә кулланыла:

а) *-ны/-ни:* дүшеңни атамыза йурутдугың [Ф. 64.14]; дүшеңни изгү мөбарәк йурам имди [Ф. 88.20]; йурусарам дүшиңни тәғбиремдә [Ф. 88.18]; бу дүшиңни һич кимсәгә сән әйтмәгил [Ф. 54.6]; рази улдым қулыңызны сатун алдым [Ф. 98.2] һ.б.

б) *-ы/-и:* әхуалеңи билү виргил дәйүр имди [Ф. 124.32]; Халиқ сәнең догаңы қабул қыла [Ф. 118.25]; қулыңызы бир күрәлүм дирләр имди [Ф. 122.8] һ.б.

III зат тартымлы исемнәр ике төрле вариантта килә: а) кыпчак төрләнеше *-ын* формасында 96 мәртәбә кабатлана; ә) угыз төрләнеше тибы өчен хас булган *-ыны/-ини* 48 тапкыр теркәлгән, кыпчак төрләнеше норма тәшкил итә. Мисаллар:

а) кыпчак төрләнеше *-ын/-ин:* арзуларин Маликә заһир қылды[Ф. 122.7]; үгүтләп аркасын сыпар имди [Ф. 168.28]; әлин (16 мәртәбә): бағбуғауын чишмәгил айагындан [Ф. 96.39; 108.22; 132.9]; ул шәһәр әһле Йусефең күркин күрди [Ф. 110.18] һ.б.

ә) угыз төрләнеше *-ыны/-ини:* Вар Иусефең арқасыны сыйфаты дәйур [Ф. 166.15]; атасыны күрүбән ғибрәт алды [Ф. 166.10; 82.15]; қәрдәшеңез қаныны күтәрмәң дир [Ф. 70.26]; хөрмәтени қәдерини бу гәз белди [Ф. 146.22]; Йусефең итини йисә қанын эчсә [Ф. 84.5] һ.б.

«Ана вә угыл»дастаныннан мисаллар: дөнйа бирип ахирәтни (اخيرتنى) алды сатун [Н. 59.2]; нәфсени (نفسنى) өлтүрмәгә қадир иди [Н. 59.11]; уғлан тәмам Кор’анне (قراننى) оқымыш иди [Н. 59.24]; җүмлә ғаләмне (عالمنى) отқа йандурмағыл [Н. 62.114].

Болгар чоры эпитафик язмаларда төшем килеше *-ны/-не* кушымчалары белән саклана һәм җөмләдә ул туры тәмамлык булып тора: galimlärne aγïrlaγan jatim tul öksüzlärne asraγan (91) [Хакимзянов, 1987, с. 49].

*Чыгыш килеше.* Чыгыш килеше күрсәткечләре Болгар чоры язма истәлекләре текстларында ике төрле вариантта теркәлгән. Хәзерге татар әдәби теле өчен хас булган *-дан/-дән* варианты «Кыссаи Йосыф» поэмасында 173 мәртәбә, ә борынгы уйгур әдәби теле өчен хас *-дин* кушымчасы 33 мәртәбә кабатлана. Чыгыш килешенең яңгырау варианты гына теркәлгән. Мисаллар: тәэвилени атасындан (اتاسندًا) сурар имди [С.Б.2а]; күкдән қушлар инәр ирде күрәр ирдим [Ф. 146.3]; адәмидән күрмәдим сәндәк нурлу [Ф. 162.27; 120.38]; керпекләрең җанымдан кәчәр имди [Ф. 162.8; 160.44] һ.б.

*-дин* кушымчалы чыгыш килеше: йәш алмадин латифрәк ийәкләрең [Ф. 162.14); қаза кәлсә бәсарәт әлдин кедәр [Ф. 58.46]; гәүһәрдин һәм кәндилләр әйләсүнләр [Ф. 154.46]; мал мөлкәтдин тәмам күңел бизмәк кәрәк [Ф. 154.11] һ.б.

Тартымлы төрләнештә этимологик *-н-* һәр очракта саклана: күзләрендән йәшләр акды [Ф. 96.35]; күзләрендән гәүһәр кеби йәшләр

акды [Ф. 124.4; 362.3]; аталары көзүндин гаиб улдылар [Ф. 62.9]; ушал хәлдә җаныңдан кэтди карар [Ф. 146.43]; қуйынумдан керүбән йақамдан чықды [Ф. 88.10]; йа әбәти дөшемдә ун қорд күрдем Йусефи әлемездән қапар имди [Ф. 62.33] һ.б.

«Ана вә угыл»дастанында чыгыш килеш кушымчалары 17 сүзформада теркәлгән, шулардан 14 очрак *-дин* күрсәткечле, өч мисал *-дан/-дән* аффикслы: барчасы ул от илендин (ايلندين) үтделәр [Н. 63.141], қаза тәңредин кәлде аңа [Н. 62.122]; шәкәрдин датлы ирди ширин сүзи [Н. 59.18]; пычақны уғлан қулындин алдылар [Н. 61.75]; [Н. 62.122] һ.б. Текстта норма булып *-din* кушымчалары тора. Бик сирәк, бары 3 сүздә *-dan* формасы очрый. буларны отдан (اوتدان) кимсәнә алмадылар [Н. 62.210]; куртар имди ошбу отдан җаными [Н. 63.145]; Хақдан аңа һәргиз рәхмәт улмайа [Н. 62.101] һ.б.

Эпитафик язмаларда чыгыш килеше бары бер мисалда *-дин* кушымчасы белән теркәлгән: fani dönjadin (182) [Хакимзянов, 1987, с. 51].

*Урын-вакыт килеше.* Урын-вакыт килеше *-да/-дә* кушымчасы белән белдерелә, урын, вакыт мәгънә мөнәсәбәтләрен белдереп килә. Мисаллар:

«Кыссаи Йосыф»: йэрдә күкдә қоллар үзә разиқ дорыр [Ф. 110.10]; қодрәт бирлә күкдә қара булут туғды [Ф. 106.22]; бән дөшүмдә күрдегүм байық дәгүл [Ф. 136.5]; дүшдә сәңа белдердиләр [Ф. 112.6]; дүшдә күрди [Ф. 128.22;128.15;158.21] һ.б.

III зат тартымлы исемнәрдә этимологик *-н* һәр очракта язылган: Йағқуб сәүчи уйлуқында (اويلقندا) уйур иди [У.И., 2а]; атамыз қашында (قاشندا) без қалалум [У.И. 4б]; Йа әбәти, дөшемдә (دوشمده) ун қорд күрдем [С.Б. 6а]; Уд эчендә (ايچندا) сақлады аны җәлил [С.Б. 8а] һ.б.

«Ана вә угыл» текстында урын-вакыт килешенең тартымлы һәм тартымсыз исемнәрдә очравы күзәтелә: йаыз ики җиһанда хақир [Н. 59.6]; күрдүм анам сәни түшүмдә [Н. 60.37]; от эчендә (اچنده) әлем айақын киселди [Н. 63.146], уғыл аның отда (اوتده) йана [Н. 63.159].

Урын-вакыт килеше кабер таш язмаларында *-да/-дә* кушымчасы белән ясалган: İsχaq otüz altï jašinda erdi (82); Šäwwäl ajïnïŋ aχrïnda erdi (213) [Хакимзянов, 1987, с. 51].

*Корал килеше. -ын/-ин, -ун/-үн* кушымчалы корал килеше иң борынгы төрки язма истәлекләрдән Орхон-Енисей язмалары, борынгы уйгыр язма истәлекләре һәм Мәхмүд Кашгарый сүзлегендә актив кулланылышта булуы күренә. Әлеге килешнең кулланылышы

нигездә аның бу чор язма истәлекләрендә берничә төрле грамматик мәгънәдә йөрүен билгелиләр. Мәсәлән: а) корал мәгънәсен белдерә, ягъни хәзерге телдәге *белән* бәйлеге урынында килә; б) бергәлек мәгънәсендә кулланыла, в) вакыт мәгънәсен белдерә [Нуриева, 2007, б. 32]. Төрки телләр тарихында бу килеш формасының алга таба кулланылышына карата тел тарихы фәнендә фикерләр төрле. Үзбәк галиме Х.Г. Нигъмәтов, мәсәлән, XI – XII йөзләрдәге төрки язма истәлекләрнең морфологик үзенчәлекләрен тикшерүгә багышланган хезмәтендә *-in (-ин)* кушымчалы корал килешенең гомумән ул чор язма истәлекләрендә сирәк кулланылуын, ә корал килеше мәгънәсенең бу истәлекләрдә *белән* бәйлеге ярдәмендә белдерелүен раслый [Нигматов, 1978, с. 23–24]. Шул нигездә соңгы чорда чыккан коллектив хезмәтләрдә дә корал килешенең кулланылышы төрки телләр тарихында XI йөзләр белән чикләнә дигән караш белдерелә [СИГТЯ, 1984, с. 36–37].

Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» әсәрендә корал мәгънәсендә, һәм эш-хәлнең вакытын белдереп, *-ин* кушымчалы корал килеше актив кулланылышта йөри.Мисаллар: улукечи җөмләси көзин күрди [Ф. 122.27]; качан анлары Йусеф көзин күрди [Ф. 114.43]; таж кийәр қаш уйнатур көзин сүзәр [Ф. 158.9]; йарлы Иусеф бақа қалды қанын аглар [Ф. 74.19]; Йусеф аны ищдеб қанын аглар [Ф. 98.17].

*-ча/-чә* кушымчалы *охшату-чагыштыру килеше.* Борынгы төрки нигез телдә охшату-чагыштыру килеше әдәби тел традициясе буларак сакланган, чагыштырмача сирәк очрый. Мисаллар: «Кыйсса-и Йосыф»: йарлы Йусеф йанларынча йәйән йэлди [Ф. 62.42); дүрлү дилчә Рәййаны мәдех қылур [Ф. 200.41]; әхуалүм бу күнгәчә заһир қылдым [Ф. 212.27]; бу дәмгәчә нитә бикер қалдың имди[Ф. 216.44]; гүрстан арасында күб зари қылдум, дәрдләрдән дәрдләрчә чуқ йүрүдим [Ф. 246.42] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында: Мостафа артынча түрт йары илә күрә келди [Н. 62.110].

Идел буе Болгар дәүләте чорында язылган истәлекләр телендә төрле килеш формаларының кулланылышын өйрәнү традицион әдәби телгә хас үзенчәлекләрнең шактый эзлекле саклануын күрсәтә. Текстларда угыз, кыпчак һәм уйгыр төркеменә караган төрләнеш типлары булу күзәтелде.

Асылда иялек, төшем, юнәлеш килешләрендә региональ төрләнеш – кыпчак тибына караган, ягъни тартык авазга башланган

кушымчаларның активлашуы һәм Идел буе Болгар чоры истәлекләрендә норма буларак кулланылуы ачыкланды.

**Хәбәрлек категориясе.** Исемнең җөмләдә хәбәр булып килүе язма истәлекләр телендә шактый киң чагылыш тапкан. Хәбәр функциясендә килгән исем сүз төркемнәренә махсус кушымчалар – хәбәрлек күрсәткечләре ялгана. Истәлекләр телендә тулы төрләнеш парадигмасы теркәлгән.

Текстларда хәбәрлек категориясенең I зат берлек саны күрсәткече – *-мән/-мен* кушымчасы: бән ул мән, дүшдә сәңа белдердиләр, қаршу чықыб, хезмәт қыл диб бойурдылар, һич қөмансез, шул кеши мән, белгел имди [Ф. 112.5–7]; безем сәййедемез Йусеф диди сәййедлекгә Йусеф бәндәң лаиқ диди бән Йусефең қолы мән [Ф. 114.6–9] һ.б.

Хәбәрлек категориясенең I зат күплек сан формасына мисаллар: андан Йәһүдә әйдүр белең бәйан, җөмләмез йуқсызлармыз қамулардан [Ф. 224.1–2]; Йағқуб нәби уғылы мыз дирсез имди [Ф. 254.36]; безим бу уғлумыз улсун имди [Ф. 146.28].

Угыз телләр төркеме өчен хас *-уз/-үз* хәбәрлек кушымчасы да тикшерелгән чыганакларда урын ала. Мисал: без хасләрүз шәрифләрүз дирсез имди [Ф. 264.28]; Исмағил нәслендән ирмеш белешдиләр безләр Исхақ нәсели вез дирләр имди [Ф. 220.19–20].

Текстларда хәбәрлек категориясенең II зат берлек сан мәгънәсе *-сән* күрсәткече белән белдерелә: килә үзен сән пәйгәмбәр сен, бел хәқыйқәт [Ф. 284.7]; бу күн буйлә шадеман сән [Ф. 236.32]; мәгәр син Йағқубә мөждәләрсән хәқыйқәт сән мөждәчи сән дәйүр имди [Ф. 270.39–40] һ.б.

Хәбәрлек категориясенең II зат күплеге текстта күзәтелми.

Текстларда хәбәрлек категориясенең III зат берлек саны түбәндәгечә белдерелә: а) *дорур* ярдәмче фигыль; ә) *ирмеш* ярдәмче фигыль һәм б) *-дур/-дүр, -тыр* кушымчасы ялганып. Мисаллар. а) ғәзраил әйдүр Йусефең исән дурур һәм аның қандалығы бәйан дурур, мәләкәт, дәүләт ийәси солтан дурур [Ф. 258.29–31]; ә) Зөләйхә мәлик Тәймус кызи ирмеш [Ф. 128.13]; в) сәнен атаң Йагқубдур бабаң Исхақ [Ф. 104.13] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында хәбәрлек кушымчалары чагыштырма сирәк теркәлгән: дин Мөхәммәд динидүр бу көн бизгә имди бәйрәм көнидүр [Н. 63.238-239].

## 1.2. Сыйфат

Болгар чоры язма истәлекләре телендә төрки-татар, гарәби һәм фарсы чыгышлы сыйфатлар кулланыла. «Кыйссаи Йосыф» поэмасында Кол Гали төрки поэтикага үзеннән яңалыклар кертә, әсәр телендәге сыйфатларның үзенчәлекле бирелеше бу күренешне ачык күзалларга мөмкинлек бирә. Әсәрнең төп герое Йосыф образын төрле яктан тасвирлау өчен шагыйрь сыйфатлардан оста файдалана. Мәсәлән, Йосыфны базарда сатканда, кыйммәт бәяле колның ун сыйфаты санала. Йосыфның йөз-кыяфәте, характерлы эчке сыйфатлары бай эпик сурәтләрдә бирелә. Төрле сыйфат тезелмәләре аша язучы Зөләйханың Йосыфка булган мөнәсәбәтен, хисләрен үтә төгәл чагылдыруга ирешкән.

Сыйфат сүз төркеме предметның, күренешләрнең статик билгесен белдерә. Төрки тел белемендә сыйфатларнның күпчелеге рәвеш кебек процессның билгесен дә ачыклап килә ала. Әдәби телдә сыйфат сүз төркемен лексик-семантик төркемчәләргә аерып тикшерү кабул ителгән. Поэмада кулланылган сыйфатларны берничә төркемчәгә берләштереп карарга мөмкин.

Әсәрдә киң таралган сыйфатларның берсе – әйбер һәм күренешләрнең төсен белдергән сыйфатлар. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә предметның төсен белдергән قزيل – *қызыл*, قرا – *кара*, اق – *ак*, ياشيل – *яшел*, ساري – *сары* лексик берәмлекләре теркәлгән. Поэмада қызыл төснең мәгънәсе бик үзенчәлекле. Текстта төсне белдерүдән тыш, затлы металл (алтын), кыйммәтле ташлар (якут, мәрҗән) белән янәшә кулланылып, байлык, затлылык, кыйммәтлелек төшенчәсен белдереп, күчерелмә мәгънә тудыралар: ики қызыл алтун қуйгыл бир йүнимдә [Ф. 88.19]; қызыл алтун йыгачлар анда диксүн [Ф. 154.22]; Ул сағ қызыл алтун улмыш иди, гәүһәр, йақут йазығ қылмыш иди, түрт йүз биң алтундан улмыш иди, бу қәдәрлу бәһа қыйммәт тутар имди [Ф. 250.1–2]; биленә қызыл алтун ычқыр бағлар [Ф. 250.43].

*Кызыл* сүзе, күчерелмә мәгънә тудырып, текстта тасвирый сыйфатлама – тезмә сүз буларак яши. Татар халкында кызыл алтын, кызыл мал тезмә сүзләре затлы малга ишарә буларак сакланган.

*Қара* сыйфатының туры мәгънәдә кулланылуы күренә: қара йүзлү, йаулақ қаты сәйасәтлү [Ф. 102.19]; қөдрәт бирлә күкдә қара булут туғды [Ф. 106.22]; мәлик андан диде ул қара қола [Ф. 108.1]; ғәҗәб төрфә, қара рәңлү зөлфләрең вар [Ф. 162.5] һ.б. «Ана вә угыл»дастанында *қара* сыйфаты күчерелмә мәгънә ала: тәк турар иркән йүзим болды қара [Н. 60.39].

*Қара* сыйфаты төсне генә белдермәгән, исемләшеп, шәүлә мәгънәсендә кулланылган: Қачан Йосыф қарасы күрүнмәс булды [Ф. 62.5].

Әсәрдә төсне белдереп килгән башка сыйфатлар теркәлгән. Мәсәлән, *ак*: бир ақ йенжү Җәбраил дута кәлди, ул йенжүне Йосыфның ағзына салды, җөмләсинә ағ атлас тун кийүрмеш иди [Ф. 226.19]; *йәшел*: алтун-көмүш, йәшел ғаләм күтәрдиләр [Ф. 208.1]; *сары ~ сарыг*: Йосыф әйдүр. Нә мәғнәдән көзең йәшлү,биңзең сары, қайғулу, бәғрең башлу [Ф. 242. 25-26]; җәмалең сарығ улмыш, нә ғоссәң вар [Ф. 152.6].

Текстта теркәлгән төс белдерә торган сыйфатларның язылышы, нигездә, бер төрле. Сары сыйфатының орфографиясендә сөйләм теле тәэсирендә традицион ауслаут ғ язуда күрсәтелмәгән очрак теркәлгән.

Тәм ягыннан билгене белдергән сыйфатлар чагыштырмача аз санлы, нигездә داتلو – *датлу ~* تاتلو *татлу,* اجي – *ачы,* شيرين – *ширин* сыйфатлары кабатланып килгәннәр. Мисал өчен: ул қойу ашнудан қалмыш иди, аны ушал Ғад кәфир қазмыш иди, дөбе дирән, суы йаулақ ачы иди [Ф. 72.1-3].

داتلو – *датлу ~* تاتلو – *татлу*: бал шәкәрдән татлу иди аның сүзи [Ф. 136.10]; әйа Йосыф сәнең сүзең датлу [Ф. 160.37]; бәнем датлу жаныма туйдыңызму [Ф. 66.15]; ғақле тәмам сүзе йаулак датлу дорыр [Ф. 120.22]; датлу җандин байық өмид кэсәр имди [Ф. 66.12]; туқызынчы холқы латиф ләфзе датлу [Ф. 140.11]; фәрештәләр сифатлу сүзең датлу [Ф. 142.14]; холқың латиф, йүзең йахту, сүзең датлу [Ф. 160.6]; фиғелең хуш, ғишқын йаулақ датлу дурур [Ф. 160.19].

*Датлу* сүзенең синонимы буларак фарсы сүзе *ширин* теркәлгән: сүзе ширин ләфзы датлу ғақлы артар [Ф. 108.38].

Тәм ягыннан билге белдерә торган сыйфатлар күпчелек очракта күчерелмә мәгънәдә кулланылган. Гадәттә ризык татлы була, шагыйрь исә Йосыф авызыннан чыккан татлы сүз, телнең татлылыгына басым ясый. Йосыфның олпатлылыгын, киң күңеллелеген, сабырлыгын, кешелеккә мәхәббәт тулы хисләрен *датлу җан* гыйбәрәсе үзенә сыйдырган.

«Ана вә угыл» дастанында да тәм ягыннан билге белдерә торган сыйфатлардан *датлы ~ татлу*, *ширин* лексемалары теркәлгән, һәр очракта күчерелмә мәгънәдә кулланылган: шәкәрдин датлы ирди ширин сүзи [Н. 59.18), татлу уйқу вирмеш иди аллаһ аңа [Н. 59.30] һ.б.

Шәхеснең тышкы билгесен белдергән сыйфатлар. Әлеге төр сыйфатлар, нигездә, кешегә, төп геройларга бәйле кулланылган. Әсәрдә, мәгънә бирелеше үзенчәлеге ягыннан әйберләрне, күренешләрне төрле яклап ачыклап килә торган сыйфатлар белән беррәттән, шәхесне

сурәтләүдә охшату-чагыштыру алымына нигезләнгән тасвирый сыйфатламаларның еш очрашуын билгеләп үтәргә кирәк. Сүзтезмәләр рәвешендә киңәйтелеп бирелгән сыйфатламалар геройларның образын тасвирлауда файдаланылган, поэтик-стилистик үзенчәлекләр тудыруда аларның рольләре зур.

Геройларының йөз-кыяфәтен тасвирлау өчен, Кол Гали төрле яклап ачыклап килә торган сыйфатлардан, киңәйтелгән сыйфатламалардан файдаланган. Борынгы төрки ташъязмаларда теркәлгән كوركلو – *көрклү* сыйфаты йөзне сурәтләүдә күпчелекне тәшкил итә: буның кеби көрклү җәмал ул дүзәтди [Ф. 126.6; 110.6]; һ.б. «Ана вә угыл»дастанында *көрүклү* сыйфаты йөзне тасвирлауда файдаланылган. Аның кем көрүклү иди көнаш йөзи [Н. 59.19-20]; курықты рәсулның көрүклү җаны [Н. 62.118] һ.б.

Борынгы төрки истәлекләрдә теркәлгән اورتلو – *үртлү*, ياقتي – *йақты* гарәпчәдән لطيف – *латиф*, фарсы теленнән кергән حوب – *хуб* сыйфатлары йөзнең матурлыгын сурәтләү өчен кулланылган: күңле мөшфиқ, биңзе күрклү, йүзи үртлү [Ф. 224.30]; холкың латиф йүзең йахту сүзең датлу [Ф. 160.6]; йүзең латиф кәлачең хуб мөрәүүәтлү [Ф. 160.39]; зиба буйың, узун сачен, хуб җәмалең [Ф. 214.30] һ.б. Әсәрдә геройларның киемнәрен сурәтләгәндә борынгы әдәби телгә хас булган *ағыр*, *иске*, *йаңы* сүзләре белән янәшә гарәп алынмалары *зариф*, *ғәба*, *хуш мөләүүән* сыйфатлары да актив кулланыла. Мәсәлән: ағыр хәлғәт кийүргел, алыб кэлгел [Ф. 198.35]; ул ғәрибең дунлары эски иди [Ф. 2208.11]; әйа Йосыф, дурғыл, зариф тонлар кигел,тоуның үзрә бир ғәба палас кигел [Ф. 232.36–37]; 853. Ул зәғифә қәрдәшеңез йарлы Динә, һич бир йаңы тун кимәди ул игненә [Ф. 246.13–14].

Йөзне тасвирлауда охшату-чагыштыру алымына нигезләнгән сыйфатламалар зур урын алып тора: күрдеңезмү бәнем рәнҗем аслы қандан, бу уғланның биңзе нурлу дуғар күндән [Ф. 176.25–27]; Висалең диларәм җан рәхәти җәмалең қуйаш кеби ғишқың қаты сурәтең ғәҗәб төрфә [Ф. 162.37–39] һ.б. «Ана вә угыл» дастанында охшату-чагыштыру алымына нигезләнгән сыйфатламалар урын алган. Мәсәлән: көрүклү йүзи бәңзәр ирди күнәшә [Н. 59.19–20] һ.б.

Шәхеснең билгеләрен җиткерү өчен йөз-кыяфәтне рәссам кебек бай төсләр-сыйфатлар аша яктырта. Кашны – ай, тешне – энҗе, яңакларны – якут, иякләрне – яшь алма, бармакларны тал чыбык белән чагыштыра: һиләлә биңзәр сәнең қашларың вар [Ф. 162.1]; йенҗү кеби ушақ дешләр түгләчидүр [Ф. 164.2]; йақутә биңзәр сәнең йаңақларың,

йәш алмадин латифрәк ийәкләрең,бал шәкәрдән датлурақ дудақларың, ики ләбең күңелемни үртәр имди. йаңы бетмеш дал чыбықдай бармақларың, мәрҗандин дүзелмеш дырнақларың, кәфүрдин артуғрақ беләкләрең, әлләрең хәрирдән йумшақ имди [Ф. 162.10–18] һ.б.

Төрки-фарсы телендәге *зиба* сыйфаты буй-сын камиллеген белдергән: зиба буйың, узун сачен, хуб җәмалең [Ф. 214.30]; Бән йатып уйур идүм дүшүм эчрә бир зиба сурәт күрдем [Ф. 130.6] һ.б.

Борынгы төрки язмаларда теркәлгән *йити* сыйфаты күзнең билгесен ачыклап килгән: йити көзләр күрмәз улуб сулдачыдыр [Ф. 164.1]. Күчерелмә мәгънәдә кулланылышы теркәлгән. ләфзың йити хәнжәр кеби җанымдан кэчәр имди [Ф. 160.38–39].

Поэмада гомумтөрки اوزون – *узун* сыйфаты чәч һәм гомер озынлыгына ишарә итә: узун сачын, хуб җәмалең [Ф. 214.30]; узун сачлар үзлеп дүшәр [Ф. 162.43]; дарайубән узун сачын үрәр имди [Ф. 60.24]; узун сачым дарайубән кем үрдәчи [Ф. 100.17]; халиқдан узун гомер теләр имди [Ф. 72.16]; аңа узун ғөмер рузи қылды [Ф. 72.19] һ.б.

Җәвад Алмаз поэмада кулланылган яшь алмадай яңаклар, йөрәкне ханҗәр кебек кисеп үтә торган җете күзләр, яңа туган айга охшаш кашлар, якутка охшаган яңаклар, энҗе кебек вак тешләр ефәктәй йомшак куллар, ак беләкләр, бал-шикәрдән татлы иреннәр, зифа буй, нечкә бил, энҗе-мәрҗән, гәүһәр-йакут кебек йөзләрчә тасвирлау чараларының татар шагыйрьләре иҗатында буыннан-буынга күчеп, хәзерге көнгәчә дәвам иттерелүен күрсәтә [Алмаз, 1960, б. 97–114].

Шушындый гыйбәрәләр ярдәмендә шагыйрь Йосыфның камил, тел тидергесез гүзәл сурәтен чагылдыруга ирешкән. Кол Галинең иҗаты Идел буе Болгар дәүләтендә гасырлар дәвамында халкыбызның зәвегына йогынты ясарлык язма әдәби традициянең булуы, тышкы гүзәллекне чагылдыру өчен телнең зур мөмкинлекләргә ия булуын һәм шагыйрьнең сүзләр белән оста эш итүен ачык дәлили.

Шәхеснең эчке дөньясын, характерын белдергән сыйфатлар. «Кыйссаи Йосыф» хезмәтен өйрәнүгә гомерен багышлаган галим Н. Хисамов Кол Галинең текстта игъланчы белдерүендә өр-яңа фактур бирелешкә «каһарманның сурәтендә һәм тулаем сюжетта автор мөһим дип санаган ун сыйфат телгә алына. Ул сыйфатлар алга таба вакыйгалар барышында чагылыш таба дип билгели [Хисамов, 2014, б. 92–94). Аның гүзәл тышкы сыйфатларын санаганда, Йосыфның сөйләшү осталыгына, телләр белүенә басым ясый. Кол Гали сөйләмнең, аралашуның шәхеснең эчке дөньясын чагылдыруда мөһим бу-

луын ассызыклый. Шәхеснең әхлакый күңел сыйфатларын: тугрылыгын, яхшы ниятен, шәфкатьлелеген, акыл көчен, кичерешләрен төрле яклап ачыклап килә торган сыйфатлар аша (гомумтөрки сүзләр һәм гарәп-фарсы алынмалары) белдерелгән.

Кол Гали әсәрендә Йосыфның хәлиткеч сыйфаты итеп тугрылык тасвирлана. Әсәрдәге төрле шартларда аның бу сыйфаты антка, бурычка тугрылык, ахыр чиктә, туган халкына, аның гореф-гадәтләренә тугрылык рәвешен ала [Хисамов, 2014, б. 231]. Тугрылык төшенчәсе текстта һәр очракта диярлек сиддик гарәп алынмасы белән (26 очрак) бирелә, синонимнары туғры, дүз ~дур чагыштырмача сирәк кулланылган: сиддиқ Йусеф җәмалын күргел диди [Ф. 72:23]; сиддиқ Йусеф мөфсидәдән кирү дүнди [Ф. 166.27]; сиддиқ Йусеф халикыни даим үкди [Ф. 158.37]; Зөләйхә әйдер. «әйа, сиддиқ нәби [Ф. 218.9]; кәлачең дил зәбан, кәләмен дүз [Ф. 162.9]; хас вә ғамә ғәдел-дөрест хөкем қылур [Ф. 202.10]; Мисыр шаһе дур мөселман [Ф. 232.1].

Гомумтөрки يخشى – йахшы, ايزكو – изгү, اريغ – арығ, гарәп теленнән احسان – ихсан, مشفق – мөшфиқ, لطف – лотыф, شريف – шәриф, سخيح – сәхих, фарсыдан مهربان – миһербан һ.б сыйфатлары геройларның уңай әхлакый билгеләрен ача. Мисаллар:

اريغ – *арыг*: нәфсе арыг күңли шадекәм улсун имди [Ф. 60.4];

ايزكو – *изгү*: бу дүш ичрә изгү сакынч сангыл имди» [Ф. 52.12]; Йусеф Рувилдин изгү сүз ишетмәди [Ф. 64.41]; һәргиз ана изгү сүз сүзләмәгил [Ф. 96.43]; дүшеңни изгү мөбарәк йурам имди [Ф. 88.20]; мәгәр безгә изгү доға қылсун имди[Ф. 108.4]; нә мәғнәдән ғилмең үкүш, изгү уғлан йахшы сөйләр ирсәң, дыңламагә сүзең йахшы [Ф. 218.14];

شريف – *шәриф*: бир шәриф қол әлеңә керәр имди [Ф. 88.24]; шәриф, латиф шөғағындан нуры балқып [Ф. 120.34];

سخيح – *сәхих*: фәсих телин, сәхих сүзин сөйләр имди [Ф. 202.18];

فصيح – *фәсыйх*: теле фәсыйх, сәхих сүзлү [Ф. 140.3];

عزيز – *гәзиз*: ғәзиз Йусеф тәмам ун бир йәшәр ирди [Ф. 52.1]; ғәзиз Йусеф ул дәмдә чықды тышра [Ф. 92.14];

عظيم – *гәзим*: бу күн үзем Мисыр эзи ғәзим солтан [Ф. 274.12];

صبرلو – *сабырлу*: морадына тиз йитәр сабырлу кеши, бу иш эчрә күрклү сабыр қылғыл имди [Ф. 132.3];

حوش – *хош*: ғәҗәбләди хәлқыны һәм хош холқыны [Ф. 2022.2] һ.б.

Текстта Йосыфның киң күңеллелеге, шәфкатьлелелеге гарәп теленнән кергән شفعتلو – *шәфәгәтлү*, مروتلي – *мөрәүүәтлү* сыйфатлары белән тасвирланган, гарәп нигезле сүзләргә *-лү* сыйфат ясагыч кушымча

ялганып ясалган: хәлауәтлү, мөрәүүәтлү сүзләрең вар [Ф. 162.6]; түртүнчи шәфағәтлү, мөрәүүәтлү [Ф. 140.5]; Зөләйха әйдүр йа миһербан мөрәүүәтлү [Ф. 160.5]; ғарибләрә дуст үзи һәм мөрәүүәтлү [Ф. 236.37], физик көчен гарәпчә قوتلي – *қуwwәтлү* сыйфаты аша бирә. алтынчы қамулардан бик қуввәтлү [Ф. 140.7]. Алп йүрәклү сүзтезмәсе Йосыфның баһадир көченә генә түгел, ә рухи көчен күрсәтә торган уңышлы чагыштыру. бишенчи алп йөрәклү һәм һиммәтлү [Ф. 140.6] һ.б.

Эчке кичерешнең билгеләрен тасвирлауда عرلو – *ғәрлү*, عدل – *ғәдил* (гарәп), اوعثلو – *уғатлу,* درست – *дөрест* сыйфатларыннан иркен файдаланган: үзе ғәрлү, хуш холықлу кемсә дорыр [Ф. 120.22]; йа Йусеф, кәлачең хуш, үзең ғәрлү [Ф. 162.25]; ғақле камил, ғилме тәмам, үзи ғәрлү [Ф. 196.21]; хөкме рәуан, ғақле тәмам, үзи ғәрлү [Ф. 210.26]; хас вә ғамә ғәдел дөрест хөкем қылур [Ф. 202.15]; ғадил кеши ғәриб нәуаз улур имди [Ф. 224.8] һ.б.

Танылган галим В.Х. Хаков поэманың эмоциональ киеренкелеге белән аерылып торуын белдерә. Сүзләрне куллануда еш кына мәгънәне көчәйтү күзгә ташлана. Бу – сөйләмнең эчке мөмкинлекләрен аеруча киңәйтә, геройларның эчке кичерешләренә карап, эмоциональ яңгыраш бирә [Хаков, 2003, б. 45]. Мәсәлән, тексттагы *йарлы* сүзендә фәкыйрьлек төшенчәсе генә түгел, анда геройның эчке кичерешләренә бәйле рухи халәте дә чагыла.

«Борынгы төрки сүзлек»тә يرلو ~ يرلي – *йарлы* сүзенең 'бедный, убогий, несчастный' [ДТС, 1969, б. 242] мәгънәләре теркәлгән. Мисалларда йарлы Йосыф сүзтезмәсе 13 тапкыр кабатланган, шулай ук йарлы Йағқуб, йарлы Динә сүзтезмәләре теркәлгән.Мисаллар: йарлы Йусеф ағлайу ардым дәйүр [Ф. 64.9]; йарлы Йусеф Йәһүдәдән шәфқәт күрди [Ф. 68.29]; йарлы тәүә Йосыфә йақын кәлди [Ф. 186.1] һ.б.

Геройларның чынбарлыкта булган барлык сыйфатлары урын алган. Алар арасында, уңайлары белән беррәттән, кайбер тискәре билгене белдергән сыйфатлар да күзәтелә: *йазуқ* (төрки сүз), *йазықлу* (төрки сүз), *сөчлү* (төрки сүз), *сөчсез* (төрки сүз), *батил* (гарәп сүзе), *фәсад* (гарәп сүзе), *мөфсид* (гарәп сүзе), *нәһи* (гарәп сүзе), *хилаф* (гарәп сүзе), *зилләт* (гарәп сүзе), *гөнаһ* (фарсы сүзе). Мисаллар: хәқыйқәт бән арумән ул йазықлу [Ф. 170.38]; йа ғәзиз, улдыр сөчлү [Ф. 170.38]; арт итәке йыртық кемсә сөчсез имди [Ф. 172.24]; бир дәм ғожөб мәйданенә җәулан қылды [Ф. 114.30] һ.б.

Кардәшлек хисләрен онытып, күңелләрен яман гамәлгә биргән туганнарын сурәтләүдә *суық бәгре қаты йүрәк* сыйфатламасы кире

тәэсир тудыруда зур роль уйный: Зәһи гөҗәб суық бәгре қаты йүрәк күнләкини игнендән суйарлар имди [Ф. 74.27]

Шәхеснең, предметның төсен, төрле билгеләрен, эчке сыйфатларын, ягъни статик билгесен белдергәндә, сыйфатлар бары исемне ачыклаган.

Предметның формасын, физик халәтен белдергән сыйфатлар.

Зат һәм предметларның зурлыгын, күләмен белдергән сүзләр арасында текстта сыйфатлар: ازاق – *узақ*, ازون – *узун*, اولوغ – *улуг*, تليم – *тәлим*, اوكوش – *үкүш*, جوق – *чок* кебек сүзләр кулланыла. Мисаллар: аһ дәригә үкүш рәнҗем узак йулым [Ф. 136:3].

*узун*: халиқдан узун гомер теләр имди [Ф. 72.16]; халиқ ана узун гомер рузи қыйлды [Ф. 72.19]; улуғ ~ улу. Йусеф улуг падишаһ улур улса [Ф. 54.26]; Мисър эчрә улуг таҗир улур иди [Ф. 88.1]; улуг қәрдәше Рауил үзә сыгынды [Ф. 64.34] ~ Мисыр эчрә Йосыф улу мәлик улды, изеси улу мәмләкәт рузи қылды; Мисыр эчрә улу хатун улур идүм [Ф. 212.36]; самәд аңа улу мөлек вирди имди [Ф. 212.36]; Йосыф улдәм йаулақ улу дәгвәт қылды, улу бәкләр үндәлүб, хазир кэлди, йаулақ улу бәшарәтләр улур имди [Ф. 216.38-40] һ.б.

Гарәп алынмасы جليل – *җәлил*, төрки اولوغ – *улуг* сыйфатының синонимы булып тора: Андан соңра вәхи изди ул хак җәлил [Ф. 70.9]; Җәлил әйдүр Җәбраилә [Ф. 168.21]; ушбу эши җәлил рәуа күрмәз имди [Ф. 66.24]. Автор Аллаһка булган хөрмәтне күрсәтү максатында аны җәлил, ягъни олуг итеп тасвирлый. Төрки اولوغ – *улуг* ~ اولو – *улу* сыйфаты шулай ук бары хөрмәт, бөеклек мәгънәсендә кулланылган: улуг кардәш, улуг мәлик, улуг дәүләт һ.б.

كجك – *кечек*: Ул кечек тыйфел уғлан ун йиде күнлек ирүр, йаңы туған [Ф. 94.37]; кечек углан тануклык вирүр имди [Ф. 170.40] һ.б.

*Дар*: мәҗрухлары дар қойуйа [Ф. 210:10]; ул дарачық қойудан кем чықарды [Ф. 182.15] һ.б.

اغر – *ағыр*: ағыр бәһайә сатун алдум [Ф. 178.17] һ.б.

يراق – *йырақ*: нә йырақ Кәнған иле [Ф. 188.1] һ.б.

انكي – *йаңы:* бәгдәзан йаңы ай йәнә дуғды [Ф. 212.41] һ.б.

Күләмне белдергән сүзләр текстта, еш кына, исемне дә, фигыльне дә ачыклап килгән. Мәсәлән, *тәлим, үкүш, чук* берәмлекләре кулланылышында борынгы әдәби телдән килә торган сыйфат, рәвеш сүз төркемнәренең дифференцияләшеп бетмәве ачык чагыла. اكوش – *үкүш* сүзе текстта 9 мәртәбә кабатланган, шулардан 8 очракта исемне ачыклап, предметның билгесен белдереп килсә, бары бер очракта эшнең билгесен белдереп килгән. Мисаллар: а) фигыльне ачыклаган: гәзиз

сәни бездән үкүш сурды [Ф. 232.10]; ә) исемне ачыклый. аны сатыб үкүш нигмәт булдачы сән [Ф. 88.26]; аh дәригә үкүш рәнҗем узак йулым [Ф. 136.3]; мөштәри үкүш бәhа вирмәсәйди [Ф. 96.11]; нә үчүн кайгың үкүш хатерең тар [Ф. 124.29];ул сәбәбдән үкүш рәхәт күрнер имди [Ф. 88.28]; фазле бирлә рузи кыла үкүш нигмәт [Ф. 52.18] h.б.

تاليم – *тәлим* сүзе текстта барлыгы 26 тапкыр очрый, шулардан 16 очракта исемне ачыклап, предметның билгесен белдереп килсә, бары 10 мисалда процессның билгесен белдереп килгән. Йусеф илә тәлим сүз сүзләшдиләр [Ф. 110.3]; кәтүрдиләр тәлим мал алтун хачлар [Ф. 132.19]; сөбхан сәңа тәлим ихсан қылур имди [Ф. 54.4]; тәлим дөрлү хәшарәтләр анда имди [Ф. 72.8] h.б.

Сыйфатланмышыннан башка килгән сыйфатлар исемләшәләр, исем сүз төркеменең категорияләрен алып төрләнәләр. Мисаллар: сәнең күшек – фани, бақи сәрай анда имди [Ф. 164.32]; күрклү-күрксез – җөмлә йуқ [Ф. 164.13]; ғәзиз ирдем – тул, ғәриб, ғаҗиз қалдым [Ф. 212.25]; улу-кечи, бай-йухсул бақар ирди [Ф. 204.39]; hәрдәм айның йаңысы улдуғында [Ф. 210.21] h.б.

Текстта сыйфат хәбәр функциясендә киң кулланылган: Ғақле камил, ғилме тәмам, үзи ғәрлү, йүзе күрклү, холқы латиф, hәзар дөрлү [Ф. 196.21–22; нә үчүн қайғың үкүш, хәтерең тар, ғәм ғоссә йар улубдыр сәңа, әй йар [Ф. 124.29–30] h.б.

*Сыйфат дәрәҗәләре.* Әсәрдә чагыштыру hәм артыклык дәрәҗәләрен шагыйрь яратып кулланган. Мисаллар:

Чагыштыру дәрәҗәсе: қамуларындин улуграк агам сәнсен [Ф. 64. 37]; батил ишдән бәңа зиндан йәгрәк [Ф. 176.36]; Йа Зөләйхә, бу уғланны хөрмәт қылғыл, ғайәт улу аңа лаиқ ғиззәт қылғыл [Ф. 146.25–26] h.б.

Артыклык дәрәҗәсе. Әсәр телендә артыклык дәрәҗәсе *йаулақ, қаты* сүзләре ярдәмендә ясалган. Мисаллар:

*йаулақ*: Қәрдәшләри муны күрүб ағлашдылар, йаулақ қаты хәсрәтилә чуғлашдылар зар вә гөрйан улуб қаты иңрәшдиләр [Ф. 100.38]; йаулак улуг шәремсар улдачидур [Ф. 78.18].

قتي – *қаты*: Кәнған иле йаулақ қаты қызлық улды [Ф. 220.1]; җөмләси ағлашурлар қаты хәсрәт [Ф. 242.7]; Йосыф сәүчи кәнде сөчин бәллү белди, бу мәғнәдән қаты йаулақ мәғмум улды [Ф. 182.29–30]; бу хәл ичрә үзи қаты зәғиф улды [Ф. 156.26].

Текстта *йаулақ, қаты* сүзләре синоним буларак бер җөмлә эчендә кулланылган: Йәнә күрдүм йите сығыр йаулақ зәғиф, йителәси қаты зәғиф, улмыш нәхиф [Ф. 194.17–18].

Поэмада әдәби тел традициясе һәм сөйләм теле җирлегендә формалашкан бай һәм сурәтләүдә камил бөтенлек тудыруга ярдәм иткән сыйфат сүз төркеме чагылыш тапкан. Әсәрләрдә зур күпчелекне төрки-татар чыгышлы сыйфатлар тәшкил итә, гарәп-фарсы теленнән кергән алынма сыйфатлар да күзәтелде. Зирәк, нечкә күңелле, илаһи дәрәҗәдә гүзәл, сабыр Йосыф, гомере буе мәхәббәтенә тугры, зифа буйлы, гүзәл Зөләйха образларын тасвирлаганда, аларга поэтик җанлылык бирү, аеруча бер сыйфатын калку итеп күрсәтү максатыннан Кол Гали сыйфат сүз төркемен гаять урынлы кулланган. Поэмада язма һәм сөйләм теленең бай мөмкинлекләре файдаланылган. Поэмада охшату-чагыштыруга корылган сыйфатларга зур урын бирелгән, сыйфатларның кулланылышында, еш кына, мәгънә көчәйтү сиземләнә.

Сыйфатлар әсәрдә гаять киң кулланылганнар һәм лексик-семантик яктан төрле мәгънәләрне белдереп киләләр. Әсәрдә шәхеснең тышкы, эчке сыйфатларын, характерын белдерә торган сыйфатлар аеруча зур урын тоталар. Әсәрдә урын алган сыйфатлар эмоциональ яңгыраш бирәләр, образ тудыруда, геройларның хис-кичерешләрен җиткерүдә зур роль уйныйлар.

### 1.3. Рәвеш

Рәвеш төрле сүз төркемнәренең формаларын саклаганга күрә, грамматик билгеләрен өйрәнү шактый четерекле. Тарихи планда рәвешләрнең формалашуы нигездә билге мәгънәсенә ия булган сүз төркемнәренең аерымлануы белән бәйләп карала [Щербак, 1987, с. 12–13). Истәлекләрдә теркәлгән рәвешләрне төрки тел белемендә кабул ителгән бүленешкә нигезләндек. Рәвеш эш-хәл билгесен яки билгенең билгесен белдерә торган сүз төркеме. Әлеге уңайдан, рәвешләрне мәгънә буенча билге һәм хәл төркемчәләренә бүлеп, лексик-семантик билгеләре ачыкланды.

Истәлекләр телендә эшнең сыйфатын, күләм-чамасын, үтәлү рәвешен, ягъни эшнең нинди дә булса билгесен белдерә торган сүзләр – билге рәвешләре төркемчәсе еш очрый.

а) эш-хәлне күләм-чама ягыннан ачыклый торган рәвешләр. Истәлекләр телендә гомумтөрки сүзләрдән: *тәлим, укүш, чоқ, күп, артуқ, тәмам,* гарәп алынмаларыннан *тәхқыйқ* лексемасы теркәлгән. Кол Гали *тәлим, укүш, чоқ, күп* сүзләрен синонимнар буларак куллана. Ясалышы ягыннан алар тамыр сүзләр. Борынгы төрки تاليم – *тәлим* (26 мәртәбә), جوق – *чоқ* (21 тапкыр), اكوش – *укүш* (9 очрак) сүзләренең

саклануы традицион лексиканың әле шактый эзлекле саклануы турында сөйли. Әлеге нәтиҗәләр статистик исәпләүләргә, сүзләрнең җөмләдәге синтаксик функцияләрен тикшерүгә нигезләнеп ясалды. Чагыштырыгыз, борынгы төрки текстларда ук теркәлгән تاليم – *тәлим* сүзе текстта барлыгы 26 тапкыр очрый, шулардан 16 очракта исемне ачыклап, предметның билгесен белдереп килсә, бары 10 мисалда процессның билгесен белдереп килгән. Мисаллар: а) фигыльне ачыклаган: аның үзрә тәлим дөруд улсун имди [Ф. 46.8]; Вәғдә йэтди дәйүб тәлим сәүнүр имди [Ф. 90.24]; йалуарыр тәуазиғлық тәлим әйләр [Ф. 160.35]; фирақ утын тәлим йутдым хәсрәтем чоқ [Ф. 164.23]; хәмдү сәна тәлим айғыл сөбханеңа [Ф. 54.3]; 579 әдәбсезлек ул уғландан тәлим күрдем һ.б.

ә) предметның билгесен белдергән: гүр эчендә тәлим күркләр бузулубән [Ф. 164.5]; Йәмәндән Мисырға бир җасус кэлди,тәлим әмвәл кэлтүреб, ришвәт вирди; тәлим мөддәт бән сәңа сүз сүзләдүм; чүрәсендә тәлим дерлү йығач улсун [Ф. 154.35]; хәлләр дүнди тәлим айлар кэлди көчди [Ф. 136.42].

اكوش – *үкүш* сүзе текстта 9 мәртәбә кабатланган, шулардан 8 очракта исемне ачыклап, предметның билгесен белдереп килсә, бары бер очракта эшнең билгесен белдереп килгән. Мисаллар: а) фигыльне ачыклаган: ғәзиз сәни бездән үкүш сурды [Ф. 232.10]; ә) исемне ачыклый. аны сатыб үкүш ниғмәт булдачы сән [Ф. 88.26] һ.б.

جوق – *чоқ* сүзе текстта барлыгы 21 тапкыр очрый, шулардан 16 очракта процессның билгесен белдергән, бары 10 мисалда исемне ачыклап килгән. Мисаллар: а) фигыльне ачыклаган. азақларыға ағнайу чоқ йалуарды [Ф. 64.31]; Йусыфа чоқ йалуарды [Ф. 108.11; 62.21; 54.43; 254.41] һ.б.; ә) предметның билгесен белдергән: қомашым атласым чоқ [Ф. 96.6]; өмидим чоқ бәнем хакдан дәйүр имди [Ф. 102.36]; солтанлардин чоқ теләрләр һәргиз вармаз [Ф. 132.33] һ.б.

Бер җөмләдә исемнең һәм фигыльнең билгесен белдерү очрагы да теркәлгән: сәнең үчүн чоқ ағлады, зари қылды, чоқ чоқ сәләм қылды сәңа дирләр имди [Ф. 232.11–12]

Күзәтүләрдән күренгәнчә, *тәлим*, *үкүш*, *чоқ* сүзләре кулланылышында борынгы әдәби телдән килә торган сыйфат, рәвеш сүз төркемнәренең дифференцияләшеп бетмәве ачык чагыла.

Халык сөйләм теле йогынтысында *күп* (3 мәртәбә) сүзенең әдәби телгә үтеп керү очрагы теркәлгән, һәр очракта эшнең күләм ягыннан билгесен белдергән: Иусефи күп үгәр имди [Ф. 132.12];

диңезләр қырағында күб ағладум, қанлы күңләкеңи дутыб күб ағладум [Ф. 246.39–40]

Эш-хәлнең күләм-чамасын белдереп, нигездә фигыльләрне ачыклап килгән рәвешләр: *артуқ ~ артық, тәмам, артуқ*. Мәсәлән, аның сидқы қамулардан артуқ имди [Ф. 46.12] һ.б.;

ارتق – *артық*: йүз биң ирдән артық ирди аның фазле [Ф. 46.15]; инчи вирсә бездән аңа артық вирүр [Ф. 56.27]; қамулардан Малик артық йалуарыр имди [Ф. 108.24]; нуры дәхи һәзар чәндан артық улды [Ф. 118.6] һ.б.

Җөмләдә хәбәр функциясен үти: хөрмәтең сәнең бездән артық имди [Ф98.36]; ғақлы күрке сездән дағы артық имди [Ф. 94.36] һ.б.; артыклык дәрәҗәсендә килә алалар. артуғрақ сәүәр имди [Ф. 128.20]; бәнән аңа артуғрақ тәғзим қылғыл [Ф. 146.27]; кәфурдин артуғрақ биләкләриң [Ф. 162.19] һ.б.

يولاق – *йаулақ* сүзе рун язулы борынгы төрки истәлекләрдә теркәлгән «бик» мәгънәсе белән кулланылган, нигездә фигыль сүз төркемен ачыклап килә, билгенең билгесен белдерә: ғашиқлықдин йаулақ рәнҗү тартар имди [Ф. 212.8] һ.б. Чагыштыру дәрәҗәсендә килү очрагы теркәлгән. бир имезни артуқырақ сәүәр [Ф. 228.11].

*тәхқыйқ*: атасы бу әхуали тәхққыйқ белди [Ф. 132.25]; бәнүм үчүн бир дога қылғыл тәхққыйқ [Ф. 142.39]; Зөләйхәнең кәсдени белди тәхққыйқ [Ф. 162.30] һ.б.

Эшне үтәлү рәвеше яки башка билгесе буенча характерлый торган рәвешләр эшнең сыйфатын белдерәләр һәм күбесенчә фигыльгә бәйләнеп киләләр:

تيز – *тиз*: Җәбраил ул ташны тиз чықарды [Ф. 76.18]; морадынә тиз йитәр сабырлу кеши [Ф. 132.3]; тиз йүгерүб мәликгә хәбәр вирди [Ф. 144.23] һ.б.

يكرك – *йәгрәк* һәм يحشي – *йахшы* берәмлекләре синонимик мәгънәгә ия, борынгы төрки *йәгрәк* сүзен шагыйрь ешрак кулланган: нә дәйүрмен әшитүбән йахшы аңла [Ф. 162.34] һ.б.

قاتي – *қаты* (15) ~ قاتيغ – *қатығ* (2) сүзенең текстта кулланылышын өйрәнү сүз төркеменең формалашуына бәйле кызыклы материал бирә. Лексик берәмлек җөмләдә предметның да, эш-хәлнең дә билгесен белдерә, исем белән дә, фигыль белән дә синтаксик бәйләнешкә керә. Чагыштыр:

а) фигыльне ачыклаган: зар вә гөрйан улуб қаты иңрәшдиләр [Ф. 100.39]; йаулақ қаты һәйбәт бирлә йағар имди [Ф. 106.24] һ.б.;

ә) предметның билгесен белдергән: бәңа қаты душман сиз улдыңыз [Ф. 68.5]; җәмалең қуйаш кеби ғишқың қаты [Ф. 160.42] һ.б.

Куллану процессында қаты лексик берәмлеге сыйфатка берегеп киткән. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, рәвешләр кулланышының нигезендә традицион әдәби телгә хас лексик берәмлекләрнең *(тәлим, үкүш, чоқ, йаулақ, артуқ)* шактый эзлекле саклануы билгеләнә, җанлы халык сөйләм теленә хас күп, артық лексемалары чагыштырмача аз урын алган, әдәби телгә үтеп керә башлаган. Шулай ук борынгы әдәби телдән килә торган сыйфат, рәвеш сүз төркемнәренең дифференцияләшеп бетмәве ачык чагыла.

## 1.4. Сан

Сан төшенчәсе – иң гомуми, иң абстракт төшенчәләрнең берсе. Шуңа күрә телдә сан төшенчәсен белдерә торган сүзләрнең тууы, аларның арта-киңәя барып, билгеле бер системада стабильләшүе кешелек фикерләвенең үсеше белән бәйләнгән. Икенче төрле әйткәндә, теләсә нинди әйбер, вакыйга һәм күренешләрнең санын билгеләргә ярый торган универсаль сан исемнәре фикерләү һәм танып белү уңышларының телдә чагылышы булып тора.

Саннар иң беренче чиратта реаль тормыштагы, объектив чынбарлыктагы предметларның микъдарын күзәтү, шуларны гомумиләштерү нәтиҗәсендә туганнар. Саннарның төп чыганагы – объектив чынбарлыкта. Ә инде кешенең шул чынбарлыктагы әйберләрнең микъдарын саный алу сәләте аның бик озак заманнар буе хезмәт һәм тормыш тәҗрибәсе арта бару нәтиҗәсендә, акыл һәм гомумиләштерү көче шактый үскәч кенә, барлыкка килгән була. Иң борынгы төрки нигез телдә үзенчәлекле, ягъни киләсе дистә санга якынаю юнәлешендәге санау системасы кулланылган, мәсәлән, Орхон-Енисей язмаларында [Нуриева, 2007, б. 34–35]. Әмма бу санау системасы төрки телләрдә шактый борынгыда ук үзгәреш кичергән һәм, хәзерге барлык төрки телләрдә диярлек, меңнәр, йөзләр дистәләр һәм берәмлекләр тәртибендәге санау системасы барлыкка килгән. XIII йөз борынгы болгар чоры язма истәлекләре телендә тулысынча яңача санау системасы чагылыш таба.

Сан, сүз төркеме буларак, микъдар төшенчәсен, предметларның сан, данә, исәбен белдерә. Сүз төркемнәре арасында саннар, башлыча, үзләренең сүзлек составы белән аерылып торалар. Сан төркемчәләрен исәпкә алмаганда, төрки телләрдә саннарның аерым төрләнешләре юк. Әсәрдәге сан исемнәре, нигездә, үзләренең төп функцияләрендә

кулланылалар, ягъни микъдар төшенчәсен, предметларның данә исәбен белдерәләр.

*Микъдар саннары.* Микъдар саны – микъдар төшенчәсен, предметның санын, исәбен белдерә. «Кыйсса-и Йосыф» әсәрендә барлыгы 156 микъдар саны теркәлгән. Истәлекләр телендә саннарның төп маясын берәмлекләрне белдергән بير, بر – бир, ايكي – ики, اوج – үч, تورت – төрт, بيش – биш, التي – алты, يتي – йети, سكيز – сәкиз, توقوز,تقوز – токуз саннары, дистәләрне белдергән اون – он, يكيرمي – йигирми, اوتوز – отуз, قرق – кырык, ايليك – илиг, التميش – алтмыш, ييتمي – йитмиш, ساكسان – сәксән, تقسان – туксан саннары очрый.

*Бир*: бир кәмпир бир киләб йеб алуб кәлди [Ф. 124.5]; бир қызым бәнүм вардыр сәңа лаиқ [Ф. 132.30]; бир қызым вар мөдам сәни теләр имди [Ф. 132.28]; бен түрт йүз йармақ иди һәм бир алтун [Ф. 98.38] һ.б.

*Ики*: ағламақдан ики күзи күрмәз имди [Ф. 100.12]; аны бездән ики артуқ сәүәр имди [Ф. 56.28]; анның күңли дүшәнмеш ики йегет [Ф. 48.1]; ики қызыл алтун қуйғыл бир йүнемдә [Ф. 88.19]; қолларындан ики қула әмер қылды [Ф. 90.39]; ул балықға ики уғыл рузи қылды [Ф. 118.31]; бирси Хәсән бирси Хөсәйен ики шәһид [Ф. 48.3]; дин мөрәүүәт икиләси ики рәшид [Ф. 48.2] һ.б.

*Үч*: үч баш буғдай йәнә йирдә қалур имди [Ф. 198.24] һ.б.

*Дөрт*: өйлә кылсун дөрт дивар арасыны [Ф. 156.2] һ.б.

*Йите ~ йәди*: йите әндам бәндләри үзүлгбән [Ф. 164.6]; қөдрәт бирлә йите қапу ачмақ бәндән [Ф. 170.10; 170.14]; Андан соңра йәди йыл дәхи кәчди [Ф. 136.41]; ун йәди күн улды тәғәм һич йәмәдем [Ф. 86.11]; йите сөнбел дағы буғдай бирлә күрдүм,йәнә йите сөнбел дағы қорур күрдүм [Ф. 194.21–22]; йәди йыл учыз ула [Ф. 198.21] һ.б.

*Он*: он қәрендәш йығлашуб утурдилар [Ф. 54.34]; ул он түн үч йүз алтмыш йулы биһуш улды [Ф. 82.13]; он бириси сәңа хезмәт қыла имди [Ф. 52.19]; он ики йыл зиндан ичрә қалмыш имди [Ф. 196.28]; ул бутақлар он икиму тәмам имди [Ф. 187.41]; он ики йыл зиндан ичрә қалмыш имди [Ф. 196.28]; Қоббә йығач дидекең Йағқуб дорыр, он бир уғлы хезмәтендә хазир дорыр, он икенчи Йусеф адлу ғаиб дорыр [Ф. 188.10-11]; он үч күндә Мисыра йитеб варырлар имди [Ф. 222.4]; он сәкез йармақ алдық [Ф. 96.21]; он сәкез йармақым вар [Ф. 96.17]; он сәкез йармақны алың сезләр [Ф. 96.19]; йигирми бед кемсәләр шәһид улды [Ф. 122.35]; йигирми төрт уғыл аңа рузи қылды [Ф. 142.43] һ.б.

*Отуз*: отуз йәшәр йэгетләрдән ирди ғөмри [Ф. 202.10] һ.б.

*Әллиг*: андан соңра әллиг йыл тәмам кәчди [Ф. 90.22]; байық әллиг йыл тәмам қалды[Ф. 90.15]; һич эксәксиз әллиг йыл тәмам турғыл [Ф. 90.17] һ.б.

*Қырық*: қырық йылдыр, ул уд бәни йақар имди [Ф. 216.12] һ.б.

*Алтмыш*: алтмыш сүңәк каму йук булдачидыр [Ф. 164.3] һ.б.

*Йэтмиш*: Йағқуб эйдүр аһ йэтмиш күн микән йухса йэтмиш ай микән аһ йухсә йэтмйш йыл микән [Ф. 80.9–11]; сандықдан йэтмиш дөрлү тун чықарды [Ф. 120.3]; күзендән йитмиш қатра дүгүлди йәш [Ф. 268.10]; йэтмиш ики: йэтмиш ики тели тәмам белүр имди [Ф. 140.4] һ.б.

*Үч йүз алтмыш:* ул ун түн үч йүз алтмыш йулы биһуш улды [Ф. 82.13]; үч йүз алтмыш әлуан дөрлү тун эйләди [Ф. 146.31] һ.б.

*Үч йөз туксан:* үч йөз туқсан кеши җөмлә йиде туйды [Ф. 112.43] һ.б.

*Бең*: биң дәүәйә хәзинә мал йүк кэтүрди [Ф. 124.13]; бең қатарә дүйә мал йүкләтдерди [Ф. 134.13]; йүз биң һәзар ғәскәр үзрә сәйасәткәр [Ф. 46.22] һ.б.

*Түмән*: ул сәрайны бу сифатлу эйләсүнләр,түмән түрлү нәқышлар бизәсүнләр [Ф. 154:38] һ.б.

Әсәрнең язып бетерү датасы һиҗри исәп белән күрсәтелгән:

Мәүләдән мәдәд, носрәт йэтүзендән,
рәҗәб ай чәлаби отузындан,
тарих чун алты йүз тоқызындан
бу зәғиф бу китаби дүзди имди [Ф. 294:9–12].

Исемләшкәндә, саннар исемнәр кебек үк морфологик категория күрсәткечләре белән төрләнәләр: Йусыф ул икесинең дүшен йурды [Ф. 180.25]; ул ишетмиш бу икендин ошбу сүзи [Ф. 54.14]; хәлиқнең бирлигинә инанасын [Ф. 90.2]; сақлар икән бирисинйауә қылдым [Ф. 58.7] һ.б.

Тартым һәм хәбәрлек күрсәткечләре алалар: дин мөрәүүәт икеләси ики рашид, бирси Хәсән, бирси Хөсәйен ики шәһид [Ф. 48.2]; ул икеси кәрамәтлү қопмыш иди [Ф. 118.33]; бириси аның Йунысны йутмыш иди [Ф. 118.34]; бирси ул һәм йүзекни йутмыш иди [Ф. 118.35]; бири кэлүб урағын кэсәр имди [Ф. 74.36] һ.б.

Әсәрдә *бир* санының кулланылышы үзенчәлекле. Ул билгесезлек артикле ролендә 38 тапкыр кулланыла: Мәүлем, сәңа сыгынурмен мән бир зәғиф тәүфиқ сәндән уманурмен мән бир нәхиф [Ф. .13.48]; Уйуркән бир ғәҗәб дүш Йусеф күрди [Ф. .23.52]; қардәшеңез Йусеф

бир дүш күрмеш [Ф. 33.54]; аһ ул йирдә бир йауыз қорд улур ирмеш [Ф. 82.26]; су эчрә бир балық улур иди [Ф. 116.37] һ.б.

Әсәрдә микъдарның өлешләрен белдерү өчен *йарым, парә* сүзләре кулланыла. Сан исеме янында ачыклагыч булганга, *йарым* сүзе алардан соң әйтелә: Зөләйхәнең мәқамедер Мәғриб иле, ирақлығы Мисыр илә аның йулы әгәр атлы ашар улса дүне күне, ай йарымда Мисыра варыр дирләр имди [Ф. 132.11–12]; Зөләйхә сурар бу хәл нидән кэлди бөтүн икән ун парә нидән улды [Ф. 148.29–30].

*Тәртип саннары.* Тәртип саны саналмыш әйбернең сан ягыннан тәртибен белдерә. Идел буе кабер ташларында *-им/-ем/-ым* һәм *-чы/-чи* кушымчалы тәртип саны теркәлгән [Хакимзянов, 1987, б. 68–69]. Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» әсәрендә эзлекле рәвештә *-ынчы/-енче* тәртип саны кушымчасы урын ала, бары «беринченең» гарәпчә «әүүәл» варианты кулланылган. Мисаллар: аһ дәригә бән әүүәл белсәм идүм [Ф. 142:29]; әүүәл улдыр кәдде йахшы зариф үзлү [Ф. 140.1]; Зөләйхә йүгерде әүүәл хазир кэлде [Ф. 170.25]; нишә халең димәдең әүүәл бәңа [Ф. 152.18]; икеләнчи кәлмәкеңез тәғҗил улсун [Ф. 228.43] һ.б.

*Җыю саннары.* «Кыйсса-и Йосыф» поэмасында җыю санының *-ыла/-илә/-ула/-үлә* формасы актив кулланыла.

*-ау, -әүләйн, -ламыз:* унуламыз сәңа тәслим кылдык имди [Ф. 98. 15]; икеләмез бутханәйә без керәлүм [Ф. 112.30]; бән сези сәүәрвән, дирикеләйен күрмәгә ауарвән [Ф. 230.18] һ.б.

«Кыйсса-и Йосыф» әсәрендә *-м/-н* кушымчалы сан кабатлап әйткәндә җыю-бүлү төсмерләрен белдерә: икен икен Йусефә кәнә сурды [Ф. 54.39]; ун кәрендәш икен икен дирнешдиләр [Ф. 6]; икен икен һәр капудән кереңимди [Ф. 23.28]; җәмален бирин бирин әйтүр ирди [Ф. 160.3]; һөнәрләрин бирин бирин әйтүр имди [Ф. 138.44] һ.б.

Идел буе ташъязмаларында исә *-м/-н* кушымчасы тәртип саны мәгънәсен белдерә: ...рәҗәп айхы оным көн эти; ...җерме үчүм җыл. Димәк, бу кушымчаны региональ күрсәткеч дип атарга тулы нигез бар.

*Бүлем саны*. Бүлем саннары *-ар/-әр, -шар/-шәр* аффикслары ярдәмендә ясала: җөмләмез бирәр уқы атдык иди [Ф. 82:22]; Йусеф суныб бирәр лоқма андан йиде [Ф. 112:42]; бирәр динар вирмәйен сезләр имди [Ф. 122:12] һ.б.

*Чама саннары.* Чама саны предметларның санын якынча, чама белән белдерә. Төрки телләрдә чама санының иң борынгыдан килгән формасы буларак *-ча/-чә* кушымчасы билгеләнә [Нуриева, 2007, б. 35].

Чама мәгънәсен белдерү өчен «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә лексик берәмлекләр: һәзар, артык сүзләре кулланылган: һәзаран афәринләр улсун имди [Ф. 48.620]; йүз биң ирдән артуқ иде аның сүси [Ф. 128.6] һ.б.

Вакытның якынча чамасын белдерү өчен махсус лексик берәмлек, аерым алганда *бир* сүзен куллану да бар: бирәр айга тигрү тәғәм йимәз имди [Ф. 204.40].

«Кыйссаи Йосыф» әсәрендә саннар символикасыннан файдалану еш очрый. Саннар, туры мәгънәдән бигрәк, күплекне, гадәттән тыш арттыруны белдерәләр. Шунысына игътибар итү кирәк: саннарның, нигездә, символик мәгънәгә ия булганнары күбрәк алына.

Җиде (йиде, йитте, җитте) борынгы заманнардан ук төрки халыкларда чик сан буларак кулланылган. Бу аның этимологиясендә дә: җиде (җитте, йитте, йите, йит) // чит // чик һәм аның белән бәйле булган сүз һәм фразеологияләрдә дә бик ачык чагыла. Поэмадагы мисаллар да авторның җиде санын символик мәгънәдән чыгып куллануын күрсәтә. Мәсәлән, Мисыр патшасының төшендә җиде саны еш кабатлана: җиде симез сыер, җиде арык сыер, җиде тук башак, җиде ач башак. Мисаллар: қөдрәт бирлә йите капу ачмак бәндән [Ф. 170.10; 170.14]; Андан соңра йәди йыл дәхи кэчди [Ф. 136.41]; йите сөнбел дағы буғдай бирлә күрдүм, йәнә йите сөнбел дағы қорур күрдүм [Ф. 194.21–22]; йиде йыл учыз ула [Ф. 198.21]; бән Йусефи күрдекүм йити йылдыр [Ф. 176.21]; йите симез сығыр күрдем [Ф. 194.13] һ.б.

*Җиде* саны төрки халыкларның дине белән дә бәйләнгән. Ислам динендә җиде уңай сан буларак исәпләнә: җәннәтнең җиде баскычы бар, хаҗ вакытында мөселман кешесе Кәгъбә ташын җиде тапкыр әйләнә һ.б.

Поэмада каһарманнарның яшьләрен биргәндә, аларның билгеле бир сыйфатларын тасвирлаганда, автор шартлылыкка, әкияти традицияләргә ияреп, саннар аша гадәттән тыш арттыруны белдерә: бәнем әгәр йүз биң җаным улур исә [Ф. 68.23]; аның гомри биң ики йүз йыл иди [Ф. 74.3]; ул ун түн үч йүз алтмыш йулы биһуш улды [Ф. 82.13]; сандықдан йэтмиш дөрлү тун чықарды [Ф. 120.3]; үч йүз алтмыш әлүан дөрлү тун әйләди [Ф. 146.31] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында саннар чагыштырмача аз теркәлгән. Микъдар саннарыннан *бир, ики, төрт, кырык, отыз үч миң, йүз миң* берәмлекләре урын алган. Мисаллар: аның бирәр уғланчығы қалмыш ирди [Н. 59.14]; йаыз ики җиһанда хақир [Н. 59.14]; Мостафа артынча түрт йары илә күрә килди [Н. 62.110]; чықамазам түрт йанка бақарам

[Н. 63.151]; қырық руза тотам йимәйем [Ф. 60.61], йүз йегерме төрт мең нәбиләр [Ф. 62.102]; утыз өч мең сәхәбә [Ф. 64.208]; йүз мең диңгезә тулдылар [Ф. 65.215].

Дастан телендә микъдар саннарының исемләшүе дә күзәтелә. Бу вакытта саннар исемнәрнең грамматик күрсәткечләрен кабул итәләр, мәсәлән: сындурмады хатун икинең сүзин [Ф. 64.190].

Бүлем һәм җыю саннары кулланылган мисаллар чикле: бирәр қучақ көтәрдиләр [Ф. 62.135]; сәвенде үбде ул икәүнең йүзин [Ф. 64.177].

## 1.5. Алмашлык

Алмашлык – бик борынгы сүз төркеме. Аларның килеп чыгышы, формалашу тарихы төрки телләрдә генә түгел, гомумән, алтай семьялыгына кергән телләрдә бик күп галимнәрнең игътибарын җәлеп иткән мәсьәлә булып санала. Истәлекләр телендә дә, алмашлыкларның күп төрле мәгънәви төркемчәләре гамәлдә йөри.

*Зат алмашлыклары.* Зат алмашлыклары сүз байлыгы ягыннан чикләнгән:

| | | |
|---|---|---|
| I зат | бән ~ мин | биз ~ бизләр |
| II зат | сән ~ син | сиз ~ сизләр |
| III зат | ул | анлар |

Зат алмашлыклары киң кулланыла, бер җөмләдә 3–4 алмашлык теркәлгән очраклар да чагылыш таба: бәйан белгел сән бәнең бән сәнеңвән [Ф. 130.25]; әйт бәңа кем сән кемнең аслындан сән [Ф. 124.23]; әйт бәңа сән кемсәдин куркырму сән [Ф. 164.35] һ.б.

Стилистик максатларда, сөйләүче белән тыңлаучы арасында каршы кую, кискенлек мәгънәсе еш очрый: бән зәғифи хикмәт таба сән йандырғыл [Ф. 48.33]; бәни қуйуб аны бәкләгил [Ф. 170.31]; Исраилдән бәни мәхрум қуйдыңыз сез [Ф. 100.7] һ.б.

Хәбәрлек белән килә: бән қадирвән тәқдири уйлә қыйлам [Ф. 168.47]; бән қадирмен нәүбәтилә сәүшдерәм [Ф. 168.41]; байық Мисыр ғәзизе бәнвән белгел [Ф. 130.46]; Тәймус ибне Талус бәнвән билиң байық [Ф. 132.29] һ.б.

بن – *бән* алмашлыгы сөйләм ситуациясенә бәйле текстта шактый актив кулланылган (62 тапкыр): андан соңра шиддәтләрдән бән қортарам [Ф. 78.13]; Валлаһ Йусефи бән күрмәдим [Ф. 84.37]; бән бу сәғәт йатур идим [Ф. 62.31]; улуларымны туйанча бән күрәйем [Ф. 98.22] һ.б.

Иялек килешендәге алмашлык һәрчак тартымлы исем белән кулланыла: بنم – *бәнем* (12) ~ بنوم – *бәнүм* (12): бәнем датлу җаныма туйдыңызму [Ф. 66.15]; бәнем әгәр йүз бен җаным улур исә [Ф. 68.19]; бәнем үчүн бир доға қылғыл имди [Ф. 118.24]; бәнем үчүн урылыңни қорбан қылғыл [Ф. 70.11) һ.б.

Төшем килеше: بني – *бәни* (28): аның ғишқы буйлә қылды бәни имди [Ф. 152.16]; атам бәни игне үзә күтәрер иди [Ф. 100.21]).

Юнәлеш килеше: بنا – *бәна* (52 тапкыр теркәлгән): бу сүзни бәна аймағыл [Ф. 74.29]; әйт бәна кем мәқамен қанда диди [Ф. 130.43]; имди бәңа кәфен улсун ушбу күңләк [Ф. 74.26] һ.б.

Чыгыш килеше: بندن – *бәндән* (12): йенҗү мәрҗан гәүһәр йақут бәндән алгыл [Ф. 140.18]; қөдрәт бирлә йите капу ачмак бәндән [Ф. 170.10]; сәййедлекгә Йусеф бәндән лаиқ [Ф. 114.7] һ.б.

بيز – *биз* (20): Йусефи биз сақлайауыз [Ф. 58.13]; атамыз қашында биз қалалум [Ф. 56.21]; атамыза игү тимар биз қылалум [Ф. 56.23] һ.б.

بيزلر – *бизләр* (4): бизләр дағы аңа бәндә булалум имди [Ф. 110.8]; бизләр йаулақ сатусаңмыз дирләр имди [Ф. 94.32]; видағ қылыб айрылалум бизләр имди [Ф. 98.24]; йукса һәләқ улдуқ қаму бизләр имди [Ф. 106.40] һ.б.

بزم – *бизем* (2) ~ بزيم – *бизим* (4) – *бизүм*: тамашамыз Йусеф улсун бүгүн бизем [Ф. 60.43]; әйдүр бизем сәййедемез Йусеф диди [Ф. 114.6] һ.б.

بيزني – *бизни* (4): бизни илгә рисва қылдың имди [Ф. 170.36]; кәрәкмәз ким бизни сөчлү билә имди [Ф. 150.8]; сизни бизни ул йаратды белең имди [Ф. 110.12) һ.б.

بيزلري – *бизләри*: йа қәрендәш сән бизләри душман көрмә [Ф. 56.13].

بيزكا – *бизгә* (8) ~ بيزا – *бизә* (5): бизә михнәт ула имди [Ф. 54.12]; нә бәһа вирәсез күрәлем имди бизә [Ф. 94.31]; пәйгамбәрләр ити бизә хәрам имди [Ф. 86.8] һ.б.

بيزلرا – *бизләрә* (3): гәреш изеси бизләрә қәһәр қылды [Ф. 106.43]; истәр исәң бизләрә билдер имди [Ф. 132.36] һ.б.

بيزدن – *биздән* (9): биздән ики артуқ сәүәр имди [Ф. 56.28]; хөрмәтең сәнең бездән артық имди [Ф. 98.36] һ.б.

بيزلردن бизләрдән: йалан дүшлә бизләрдән сәүклү улдың [Ф. 64:7];

II зат алмашлыкларының кулланылышы түбәндәгечә:

سن – *сән* (73): адәмидә күрмәдем сән сифатлу [Ф. 142.15]; сән йалан дүш күрдең [Ф. 64.5]; атамыза ул дүши сән хуб йурутдың [Ф. 64.6]; Зөләйхә сәнең ула сән аның сән [Ф. 170.3] һ.б.

سننك – *сәнең* (21): аналардан сәнең кеби дуғмаз имди [Ф. 162.28]; Йусеф сәнең сүзең датлу [Ф. 160.37]; бән сәнең әмереңә мотиғ улам [Ф. 154.6]; бу нәқышне сәнең үзә кем йүретди [Ф. 110.7]; галәм эчрә сәнең адың мәшһүр ула [Ф. 52.21] һ.б.

سني – *сәни* (24): анлар сәни сатдылар кәм йармақға [Ф. 98.33]; сәни кирү ала идүк [Ф. 100.41]; бән сәни қачан бунда сатам идем [Ф. 142.30]; бонлар сәни қул дәйүбән бәна сатды [Ф. 96.26]; Мәшриқ Мәғриб улулары сәни билә [Ф. 52.22]; сәни бәңа сатанлар кимләр диди [Ф. 144.2] һ.б.

سنا – *сәна* (7): сәна бу казаны тәңри вирди [Ф. 94.22]; кемсә сәна бәһа тикүрер имди [Ф. 124.28]; хәмдү сәна тәлим айгыл сөбханеңа [Ф. 54.3]; һәр хәл эчрә сәна пәнаһ кылдум имди [Ф. 106.4] ~ سنكا – сәңа [54]. әгәр санәм дүнеб сәңа сүзләр исә [Ф. 112.25]; бән улмән душдә сәңа белдердиләр [Ф. 112.6]; бир қызым бәнүм вардыр сәңа лаиқ [Ф. 132.30]; бу дүш эчрә солтанәт күрнүр сәңа [Ф. 54.2] һ.б.

سندن – *сәндән* (7) ~ سندين – *сәндин* бу ишни диләмәде сәндән имди [Ф. 148.32]; диләкләри байық сәндән айрылмақға [Ф. 98.34]; сәндән айру бирәр дәм булумазмен [Ф. 160.47] һ.б.

سنسز – *сәнсез* (2): бир ләхзә сәнсез кәрар қылумазмен [Ф. 160.46]; сәнсез безгә улмасун ушбу җиһан [Ф. 134.42] һ.б.

سنسن – *сәнсен* (4): ата урныға ушбу күн атам сәнсен [Ф. 64.38]; атам кеби ағам сәнсен [Ф. 64.36]; камуғындин миһербанем сәнсен [Ф. 64.47]; қамурындин улуғрак ағам сәнсен [Ф. 64.37].

سيز ~ سز – *сиз*: аны байық сиз алмышсыз [Ф. 92.40]; билдем бәндән бизар улдыңыз сиз [Ф. 100.5]; Исраилдән бәни мәхрум куйдыңыз сиз [Ф. 100.7]; сиз бәни сатармусез [Ф. 94.9]; сиз дыңлаңыз ул сүзләсүн [Ф. 56.40]; бәңа қаты душман сиз улдыңыз [Ф. 68.5]; варың сиз ул корди эстәң дутың [Ф. 84.13] һ.б.

سيزلر – *сизләр* дип тыңлаучылырга, укучыга мөрәҗәгать итә: заһир ғәйан билүрмүсиз сизләр аны [Ф. 48.15]; силәр дағы тәңридән қорқың имди [Ф. 70.16]; бирәр динар вирмәйен сизләр имди [Ф. 122.12]; қалдырыңыз башыңызы җәмеғ әйләң имде сезләр ғақлеңези мәғлүм идең сизләр бәңа хәлеңези нә хаҗәтә кәлдеңез әйден имди [Ф. 226.24] һ.б.

Улларына *сиз* һәм *сизләр* дип мөрәҗәгать итә: иртә кәлең сизләр диди ушбу кичә [Ф. 60.35]; Йүсефи сизләр бәндән диләдиңез [Ф. 84.101]; тәмуғ эчрә бақи калмаң сизләр имди [Ф. 68.44].

Хөрмәт йөзеннән Кыйтфирга,хөкемдарга сизләр дип эндәшә: сизләр аны бәнем үчүн сатун алың [Ф. 138.34]; сизләрә һич миннәтем йуқдыр имди [Ф. 144.44] һ.б.

سزننك – *сезнең* ~ سزلرننك – *сезләрнең*: Йусефем сезнең илә вармаз ирмеш [Ф. 58.18]; сезнең билә йәрин варсун [Ф. 58.52] ~ сезләрнең морадыңыз [Ф. 84.9] һ.б.

سزكا – *сезгә* (4) ~ سيزا – *сизә* (2) ~ سزلرا – *сезләрә* (3): күрдекендән сизә кәлүб хәбәр вирсүн [Ф. 56.39]; ул кәлмәки сизә йаулақ қутлу дурур [Ф. 120.21] ~ бу иш ичрә сезгә гөман қылдым иди [Ф. 68.10]; җөмләсени сезгә фида қылдым имди [Ф. 68.20]; сезгә ғәзим афәт вирә изим бары [Ф. 84.18] һ.б. ~ мөдам анлар сезләрә тәпуғ қыла [Ф. 132.43]; мән сезләрә нә сөч қылдым [Ф. 64.4] һ.б.

سزي – *сәзи* (3) ~ سزني – *сезни* ~ سيزلري – *сезләри:* бэкләсүн халиқ сези [Ф. 54.15]; улуларим имди сәзи қанда күрәм [Ф. 100.27]; шәйтан сәзи гөмраһ қылыб аңа уймақ [Ф. 74.22]; сезни безни ул йаратди белең имди [Ф. 110.12]; мәдәд бирлә сезләри бәнқ каушдырам [Ф. 168.42].

III зат алмашлыгы اول – *ул:* анлар сатар ул сатун алур улды [Ф. 94.7]; ул кичә қачан кәлүр [Ф. 60.36]; بني бәни ул уғыллықға қабул қылды [Ф. 160.23]; бу қаз аны үстүмә ул йүретди [Ф. 126.7]; бу серри ул уғлан йәгрәк билүр имди [Ф. 144.36]; бу сүзи ул ишедеб гәҗәбләде [Ф. 112.9]; бу тунлары хәқиқәтдә ул бойурар [Ф. 146.39] һ.б.

اني – *аны:* аны биздән ики артуқ сәүәр имди [Ф. 56.28]; аны күргәч бикәрар бихуд ула [Ф. 156.17]; аны көрүб барчалары хәйран қалды [Ф. 114.29]; атамыз аны бездән артуқ сәүәр [Ф. 56.25]; заһир ғәйан белүрмүсиз сезләр аны [Ф. 48.15] һ.б.

انلر – *анлар* (37): андан кэчди дигәр шәһрә анлар керди [Ф. 110.17]; анлар анда Йусефи күтәрдиләр [Ф. 62.27]; анлар бу гәз Йусефи алдадылар [Ф. 58.21]; анлар сатар ул сатун алур улды [Ф. 94.7]; боны ишдүб анлар җөмлә дирнешдиләр [Ф. 84.21] һ.б.

مونلر – *мунлар*: мунлар әйдүр ул иши кылмайауз [Ф. 96.13] һ.б.

انلرينك – *анларың:* Йусеф анларың йауыз тәдбирени билди [Ф. 64.33] һ.б.

انلره – *анлара* (7): бу кәлачи анларә сәуаб кәлди [Ф. 70.29]; Йусеф дүшин анлара әйтү вирмәз [Ф. 54.37] һ.б.

مونلره – *мунлара:* муны қул диб мунлара сатам имди [Ф. 92.48] һ.б.

انلري – *анлары:* қачан анлары Йусеф күзин күрди [Ф. 114.43] һ.б.

انلردن – *анлардан* (2): бу гәз Йусеф анлардан һәм қорықды [Ф. 96.33]; йазуқымны анлардан бән диләйәлүм [Ф. 98.23] һ.б.

انونك – *ануң* (2): ануң хөрмәти қамудан артуқ имди [Ф. 110.48]; ануң илә бөйлә улам [Ф. 118.10] һ.б.

انينك – *аның* (51): аның ады Малик ибне Дәғир иди [Ф. 88.2]; аның күңли дүшәнмеш [Ф. 48.1]; аның хөкмен һич кимсәнә йықмаз имди [Ф. 126.8]; бириси аның Йунысны йутмыш иди [Ф. 118.34]; җөмлә малум аның үчүн фида әйлән [Ф. 138.35]; Зөләйхә сәнең ула сән аның сән [Ф. 170.3] һ.б.

موننك – *муның:* ун дөрлү һөнәре вар муның дирләр [Ф. 138.43] һ.б.

اني – *аны* (51]: аны көреб барчалар бихуд улды [Ф. 114.23]; йылан чайан қурт кымырска аны ашар [Ф. 162.42]; аны сатун алумады [Ф. 138.5]; сезләр аны бәнем үчүн сатун алың [Ф. 138.34] һ.б.

Зат алмашлыкларына килеш белән төрләнү хас. Мисаллар: җаным қайгусы букүн мәңа ул [Н. 60.60], күрдүм анам сәни түшүмдә [Н. 60.37]; харам улсын имезгән сөтем сәңа [Н. 60.36] һ.б.

*Сорау алмашлыклары.* Сорау алмашлыклары борынгы төрки телдән үк килә торган тамыр алмашлыклардан *кем, ни ~ нә*, *ка-* нигезендә формалашкан, текстта сораулы сөйләм оештыру өчен кулланылган.

كيم ~ كم – *ким* (33 тапкыр теркәлгән), күплеге *кимләр* алмашлыгы затны алмаштырып килә һәм функцияләре белән зат алмашлыгына якын тора: әйт бәңа ким сән дәйү сорар имди [Ф. 142.16]; ағлар исәм күзим йәшин ким силдәчи [Ф. 100.14]; әйт бәңа ким сән кемнең аслыңдан сән [Ф. 124.23]; буның кеби күреклү җәмал ким дүзәтди [Ф. 110.6]; сәни бәңа сатанлар кимләр диди [Ф. 144.2] һ.б.

*Кем* алмашлыгының турыдан-туры кеше мәгънәсендә йөртелгән кемирсә формасы очрый, бу форма «Котадгу билик» текстыннан ук башлана [Җәләй, 2000, б. 139]: сәңа биңзәш һич кемирсә дугмыш дәгүл [Ф. 124.34]; мәгәр бездән кемирсә золем күрди [Ф. 106.41] һ.б.

Сорау алмашлыкларының бер өлеше *қан-* нигезендә формалашкан. қан борынгы тамыры белән бәйле алмашлыклар тотрыклы сакланган. Мисаллар:

قندا – *қанда*: әйт бәна кем мәкамен қанда диди [Ф. 130.43]; бунча фитнә дүшән қола сабыр қанда [Ф. 158.15]; мондан соңра бәни қанда күрәр имди [Ф. 66.28; 102.8; 100.27] һ.б.

قندالغن – *қандалыгын*: бән аның қандалыгин белсәм иди [Ф. 130.14]; қандалыгын бәлүмәди [Ф. 104.26; 84.38] һ.б.

قندن – *қандан*: бу кәрамәт бу бәрәкәт қандан имди [Ф. 144.32] һ.б.

قندا – *қанда:* һәр кем қанда қылдугын күрүр имди [Ф. 148.40] һ.б.

قاني – *қани:* аһ дәригә қани бәнем ул дәүләтем [Ф. 142.9]; қани бәнем Йусефем [Ф. 82:20]; бу күн үлсәм қани бәңа кәфен кәрәк [Ф. 74.25] һ.б.

قنقي – *қанқи:* қанқи дуст гүр эчендә аны күрсә [Ф. 162.39]; қанқи душман бәни қапа дидем имди [Ф. 68.4]; қанқи кемсә сәна бәһа тикүрер имди [Ф. 124.28]; қанқи солтан уғылы сән дәйүр имди [Ф. 124:24];

قنقسينا – қанкысына: қанқысына йалуарырса бушар имди [Ф. 74.8] һ.б.

قجان – *қачан:* Анлар қачан бу мәғнәдән хәбәр белди [Ф. 92.37]; аһ дәрирә қачан ула висал күни [Ф. 162.22]; буны қачан алур тикмә кеши [Ф. 138.38]; бән сәни қачан бунда сатам идем [Ф. 142.30]; Йусеф қачан Мисыра йақын кәлди [Ф. 120.41]; қачан ләшкәр Йусефә йақын кәлди [Ф. 114.21]; қәрдәшемез қорддан қачан қапдырауыз [Ф. 58.10; 58.14] һ.б.

*Қачанкем*: қачанкем башыға ғақлы кәлди ирсә [Ф. 134.37] һ.б.

Борынгы нигез телдән килгән ني – *ни*, نه – *нә* алмашлыкларының текстта тамыр хәлендә кулланылышы күзәтелә, 65 мәртәбә кабатлана: күңелендә нә кәчәр нә тиләйүрсән [Ф. 130.2]; әйдер нә ағлар сән [Ф. 130.1]; әйт бәңа бу арада нә хикмәт вар [Ф. 124.31] һ.б.

*Нә* алмашлыгы нигезендә башка төрле сорау алмашлыклары ясалган. Мисаллар:

نجا – *нәчә:* нәчә бәһа диләрсә вирең имди [Ф. 138.36]; нәчә бәһа кәрәк ирсә бәйан қылғыл [Ф. 140.19]; бир нәчә дерәкләри инҗү улсун [Ф. 154.26] һ.б.

نجاسي – *нәчәсе:* бир нәчәсе қызыл мәрҗан улсун имди [Ф. 154.28];

*нәчүк:* ул халиқ бу санәми нәчүк күрүр [Ф. 148.34]; ушбу ишне сән нәчүк рәуа күрдең [Ф. 170.34]; хали улмыш хәзинә нәчүк тулды [Ф. 144.31] һ.б.

نجون – *нәчүн:* Йа Йәһүдә гәһдемездән нәчүн калдың [Ф. 68.33]; нәчүн бөйлә қачар сен дәйүр имди [Ф. 104.36]; нәчүн йидең [Ф. 84.28] һ.б.

نيتا – *нитә* ~ نتا – *нәтә:* бән самәдем нитә үртсәм улур имди [Ф. 166.40]; без күрәлүм нитә җәуаб вирә имди [Ф. 112.32] һ.б.

نيتك – *нитәк:* Йусефем нэтәк сүзүң суйайын диди [Ф. 58.39]; атамыза әхуәл нэтәк белдерәсиз [Ф. 66.19] һ.б.

نيتلكن – *нитәлеген*: бәнем халем нитәлеген күзең күргил [Ф. 102.26] һ.б.

نيشا – *нишә:* бу нә ирдер нишә калды дәйүр имди [Ф. 134.28]; нә сөч кылды нишә качды дугры сөйләң [Ф. 94.35]; нишә бөйлә идәрсиз уйаларым [Ф. 64.3]; нишә сатды нишә бөйлә учыз вирди [Ф. 144.3] һ.б.

نجا – *нәчә*: йармакым вар бир нәчә кыйммәти йук [Ф. 96.7]; нәчә бәhа алур сез әйдең имди [Ф. 96.4]; нәчә дөрлү гәйбе вардыр кылың бәйан [Ф. 94.42] h.б.

نیجالرر – *ничәләр*: бир ничәләр заhирени хуб күрдиләр [Ф. 122.29]; бир нәчәләр рисаләтдән хәл күрдиләр [Ф. 122.31] h.б.

نجوك – *нәчүк*: нәчүк бу бәләйә дүшдең имди [Ф. 104.4]; нәчүк сәүдә кылурмез [Ф. 96.8]; адың нәчүк, қандағы сән [Ф. 90.42]; аның тәғбир белдүгин нәчүк белдең [Ф. 196.13]; зиндана ул нәчүк кермеш [Ф. 196.25] h.б.

*нәлүк*: сәнең кеби мәлик путә тапмақ нәлүк [Ф. 112.19] h.б. –

«Ана вә угыл» дастанында теркәлгән сорау алмашлыклары түбәндәгеләр: كيم – *ким*, نا – *нә*, قاني – *қани*, قلاي – *қалай*, قنقي – *қанқи*, نجا – *нәчә*.

*Ким* сорау алмашлыгы истәлек телендә бары тик затка, шәхескә карата гына кулланыла. Мәсәлән: Хақ бәлүр аңа кимдән ким әйләрем [Н. 62. 116]; Хақ белүр кем қайғулары йийәсен [Н. 62.121]; нәчә ким чагырды hич чара булмады [Н. 63.157]; кимсәнең михнәтин йимәз иди [Н. 59.8].

*Нә* алмашлыгы кешедән башка тереклек ияләренә hәм җансыз предметларга мөнәсәбәттә кулланыла: нә ул йийәсен, нә кийәсен белер иди [Н. 59.12]; күр нә кәлди аh бәнем башыма [Н. 62.152]; нә кәрәкдүр қылайын [Н. 62.130] h.б.

Дастан телендә сорау алмашлыклары риторик сорау төзүдә дә катнаша: қани йарымыз қәрендәшемез [Н. 63.161]; қанқи ғаурәт оғланын утқа йақар [Н. 64.202], қалай ана ким анасының күңүлүн йықар [Н. 61.67].

Тикшерүдән күренгәнчә, «Ана вә угыл» дастаны телендә сорау алмашлыклары риторик сорау төзү өчен файдаланылган. Бу исә сөйләмнең эмоциональлегенә, тәэсирлелегенә йогынты ясый.

Истәлекләр теленә теркәлгән сорау алмашлыкларын шул рәвешле күзәтеп чыгу, XIII гасыр Идел буе язма истәлекләрендә шактый үзенчәлекле, борынгы төрки чор язма истәлекләре өчен хас алмашлыкларның актив кулланылышта йөрүен күрсәтә.

*Билгеләү алмашлыклары.* Истәлекләр телендә борынгы төрки әдәби телдән килгән *кәндү, өз* билгеләү алмашлыклары актив кулланыла. Тамыр хәлендә предметларны hәм затны ачыклап, аергыч ролендә килүләре теркәлгән:

كندي – *кәнди* (6 мәртәбә) ~ كندو – *кәндү* (3 тапкыр): кәнди әлилә Йусефең башын йуды [Ф. 60.23]; кәнди әлин Йусефең башын тарар [Ф. 146.41]; кәнди әлин ул қорда аш йэдерди [Ф. 86.18] h.б.

Алмашлыкның килеш һәм сан белән төрләнеше теркәлгән: бети йазыб кәнделәрдән шәфқәт үзди [Ф. 98.10]; аш йэдерде кәндеси су эчүрди [Ф. 60.25]; кәндүләрең миһринә уд йақдылар [Ф. 74.6]; кәндүдән сабыры кэтди бихуд улды [Ф. 140.15] һ.б.

اوز – *үз* алмашлыгы нигез формасында сирәк кулланылган, күпчелек очракта тартым белән формалашкан, килеш белән дә төрләнә: һәр кеши үз лайықын ишләр имди [Ф. 98.44]; җөмләсинең гақле тәмам үзи гәрлү [Ф. 116.7]; бу хәл ичрә үзи қаты зәғиф улды [Ф. 156.22]; боны ишедүбән үзи күйәр [Ф. 98.25] һ.б.

*Кәнду* һәм *үз* алмашлыклары, нигездә бер үк мәгънә белдерәләр, текстта кушма төрләре дә очрый: кәндүзем Йусефә йар улсаммән [Ф. 82.35]; кәндүземи мәгсийәтдән бән сақлар мен [Ф. 164.38]; кәндеүзи бир сәумәгнең эчрә керди [Ф. 126.19] һ.б.

Билгеләү алмашлыклары мәгънәсендә кулланыла торган *қаму ~ қамуг*, *барча*, *җөмлә* сүзләрен, шулай ук *һәр* сүзе катнашында ясалган алмашлыкларны билгеләргә мөмкин. Гарәп теленнән кергән җөмлә алмашлыгы текстта 128 тапкыр, төрки лексемалар чагыштырмача сирәк кулланылган: қаму (21), қамуг (3) барча сүзе 14 тапкыр кабатлана:

قمو – *қаму* (21), قموغ – *қамуг* (3): алтмыш сүңәк каму йук булдачыдыр [Ф. 164.3]; дирнешдиләр қаму улу қарауашлар [Ф. 136.17]; қамугындин миһербанем сәнсен [Ф. 64.47]; қамусы аның сүзин рәуа күрди [Ф. 70.31] һ.б.

بارجا – *барча* [11], بارجه [3]: анлар әйдүр қабул қылдуқ барча сүзүн [Ф. 60.41]; кәлең барча истиғфар қылың имди [Ф. 106.36] һ.б.

جمله – *җөмлә*: аны ишедеб балықлар җөмлә қачды [Ф. 116.41]; анлар җөмлә бу сүзи рәуа күрди [Ф. 98.5]; әлең алуб җөмлә тәүбә қыла идүк [Ф. 100.42]; әлуан йирләр ақар сулар җөмлә күрсүн [Ф. 56.37] һ.б.

Фарсы теленнән кергән *һәр* алмашлыгы шулай ук актив кулланылган, бер төрдәге предметларны сан ягыннан җыеп күрсәтә: асмарлады һәр биринә учдин уча [Ф. 60.34]; әйдүр һәр йыл бу малик мондин кэчәр [Ф. 10.30]; варубән ул қойуйа һәр күн бақар [Ф. 86.26]; һәр замандә күкләр таба нәзар қылса [Ф. 148.5]; һәр кем бәңа бақар булса гақлы шашар [Ф. 114.34]; һәр кеши үз лайықын ишләр имди [Ф. 98.44] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында шундый ук традицион әдәби телдән килә торган «Кыссаи Йосыф» теленә хас билгеләү алмашлыклары урын алган: кәндү, кәндүз,қаму, җөмлә . Мәсәлән: парә парә әйләди кәндү үзүни пычақ алды кәндүзүн ормаға анасы үчүн кәндү җанын

уирмәгә [Н. 61.72–74]; кәндү әлең бирлә безне атғыл удә [Н. 63.168]; кәндү туруб йыракдин нәчә бақар күтәрди кәндүзене атды удә [Н. 64.203–204] һ.б.

Билгеләү алмашлыкларының күпчелеге сыйфат сүз төркеме белән мөнәсәбәттәш һәм алар предмет билгесенә күрсәтәләр: җүмлә ғаләмне утқа йандурмағыл [Н. 62.108]; сәлам бирдиләр җүмлә билә [Н. 62.112], һәр бири бирәр қучақ күтәрдиләр [Н. 62.135]; Хақдан аңа һәргиз рәхмәт улмайа [Н. 62.102] һ.б.

Исемләшкәндә, билгеләү алмашлыклары тартым белән төрләнәләр: қамусы тәқбир салауат бирдиләр [Н. 65:237]; җөмләси қанат қанатқа урдылар [Н. 65:225].

*Билгесезлек алмашлыклары.* Билгесезлек алмашлыкларыннан *ким* алмашлыгына нигезләнеп ясалган кимсә كيمسه, كمسا – *кимсәнә* һәм كم ارسه – *ким әрсә* лексик берәмлекләре очрый.

«Кыссаи Йосыф» тан мисаллар: бәһа йэтүреб кимсә йакын кәлүмәди [Ф. 138.6]; сәңа биңзәш һич ким ирсә дуғмыш дәгүл [Ф. 124.34]. «Ана вә угыл» дастанында билгесезлек алмашлыклары сирәк китерелә. кимсәнең михнәтин йимәз иди [Н. 59.8]; һич ким сәнә кәләч димәйим [Н. 60.62]; ут қатына кемсәнә бармадылар буларны утдан кимсәнә алмадылар [Н. 65.209-210].

*Юклык алмашлыклары.* Юклык алмашлыклары *ким* сорау алмашлыгына *һич* кисәкчәсе ялганып ясалган, сирәк кулланылышка ия. Җөмләдәге вазифасы белән исем һәм рәвеш сүз төркемнәренә мөнәсәбәте билгеләнә.

«Кыссаи Йосыф» тан мисаллар: һич кемсә күрмеш дәгүл сән дидарлу [Ф. 162.26]; һич кимсәнә бирин бирси күрмәз улды [Ф. 106.29]; һич кимсәнә бу серри белмәз ирди [Ф. 136.27]; һич кимсәнә сән сифатлу улмыш дәгүл [Ф. 124.35]; һич бириси Йусефә рәхим қылмады [Ф. 64.26] һ.б.

«Ана вә угыл» дастаныннан: бунларның хатырын һич қуймады [Н. 63.189]; һич кем сәнә кәләч димәйим [Н. 60.63] һ.б.

*Күрсәтү алмашлыклары.* Тикшерелгән чыганакларда борынгыдан килгән: *ол*, *бу*, *шол*, *ошбу*, *шөйлә*, *ушал* алмашлыклары кулланылган. Күрсәтү алмашлыклары контекстта исемләшеп, зат алмашлыклары кебек үк, килешләр белән төрләнәләр. Аларның төп функциясе – предметларга төбәп күрсәтү аша билгеләү.

اول – *ол* сүзе бер үк вакытта III зат алмашлыгы һәм күрсәтү алмашлыгы булып йөри: ол сарай андан сәңа лаиқ дурур [Ф. 160.17];

сәүенүбән мән аны дирүр идем [Ф. 88.13]; уд эчендә саклады аны җәлил [Ф. 70.7].

*Аны* һәм *муны* алмашлыклары синоним буларак кулланыла. Чагыштыр: Зөләйхә муны ишедүб үрә дорды [Ф. 132.5]; муны ишдеб Зөләйхәнең гақлы шишди [Ф. 134.33]; муны ишдүб Мисыр әһле җөмлә кәлди [Ф. 124.1]; муны ишдүб Йусеф зари ағлар имди [Ф. 94.8] ~ аны ишдеб Йагқуб нәби варсун, диде [Ф. 60.21]; аны ишдеб қәрдәшләри ағлашдылар [Ф. 74.41]; аны ишедеб балықлар җөмлә қачды [Ф. 116.41] һ.б.

اوشل – *ушал*: ушал Қәнганнең қол угланы [Ф. 152.13]; Йусеф ушал балық илә әсәнләшди [Ф. 118.37]; Йусеф ушал йэрдә йүзин дүшәр имди [Ф. 64.44]; ушал йирдә Йусефни йиргә салдылар [Ф. 62.10]; ушал күндә унар алтун тәмам улды [Ф. 122.26]; зиндана ул нәчүк кермеш,нә сөч қылмыш, ушал уғлан нә эшләмеш [Ф. 196.26–27] һ.б.

شول – *шул*: һич гөмансез шул кишимән белгел имди [Ф. 112.8]; шул қәдәр бәһа илә алды сатун [Ф. 98.39]; шул қойудан су кәтүрең [Ф. 90.40]; шул қул ғибри уғланчықны урдым имди [Ф. 106.48] һ.б.

اوشبو – *ошбу*: ошбу иш ошбу сүз растму диди [Ф. 96.27]; имди бәңа кәфен улсун ошбу күңләк [Ф. 74.26]; дүшдә күрдүгең ошбудур белең имди [Ф. 110.44] һ.б.

شوويلا – *шөйлә*: гашиқның арзусы шөйлә булур [Ф. 152.22]; Зөләйхә атасына шөйлә ирди [Ф. 128.19]; шөйлә икән бутә табу қылур ирмеш [Ф. 128.10]; шөйлә икән Йусеф деләр ғисмәт йулын [Ф. 158.27] һ.б.

*Күрсәтү алмашлыклары.* Күрсәтү алмашлыклары «Ана вә угыл» дастаны текстында зат яки әйберләргә күрсәтү, сыйфат яки рәвешләргә ишарә итү өчен кулланыла һәм лексик составы ягыннан «Кыссаи Йосыф» әсәрендә кулланылган алмашлыклар белән тиңдәш: *бу, ол, ошбу, шул.*

*Ол* алмашлыгы язма истәлек телендә еш очрый, 27 тапкыр теркәлгән, сөйләм субъектына таныш, билгеле булган предметны белдерә: хәбәр улды ол Хәсән Хөсәйинкә [Н. 63.159]; Мостафа ол хатунны билүр иди [Н. 61.81]; ол хатунның халәли өлмеш иди [Н. 59.13] һ.б.

بو – *бу*, اوشبو – *ошбу*, شول – *шул* кебек күрсәтү алмашлыклары әсәр телендә шулай ук актив кулланыла: сән йари қыл бу бичара қоллара [Н. 65. 223]; куртар имди ошбу утдан җаными [Н. 63.45]; ушал дәм дөштем тик айағына [Н. 60.43]; ошбуны мән йазмадым йазды каләм ошбуның артындин чуқ чуқ сәлам [Н. 65.242–243] һ.б.

Идел Болгарстаны чорында иҗат ителгән әсәрләрнең телендә алмашлыкларны куллануда борынгы төрки, карахани-уйгыр әдәби телләренә хас үзенчәлекләр ачык аерымлана, шул рәвешле аларда традицион уртаклыклар саклана. Бу чор язучыларның гомумтөрки әдәби традицияләрдән иркен файдалануын күрсәтеп тора.

## 1.6. Фигыль

Болгар чоры язма истәлекләре телендә фигыль күп төрле грамматик формаларда теркәлгән катлаулы сүз төркемен тәшкил итә. Фигыльнең грамматик категорияләре аның төрле төркемчәләрендә төрлечә чагылыш таба. Борынгы төрки истәлекләрдә үк, зат-сан белән төрләнү-төрләнмәүләренә бәйле ике зур төркемчә аерылып чыгарыла – затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр. Затланышлы фигыльләр булып түбәндәге фигыль формалары санала:

хикәяләү наклонениесе;
боеру наклонениесе;
теләк наклонениесе;
шарт наклонениесе.

Затланышсыз фигыльләрдә эшнең үтәүчесе махсус зат-сан кушымчалары белән белдерелми. Истәлекләр телендә сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль төркемчәләре очрый. Алар асылда фигыль формалары булсалар да, алар башка сүз төркемнәре белән уртаклык күрсәтәләр. Истәлекләрне өйрәнүдә төрле юнәлешләрдә шактый җентекле эш башкарылган. Бу чор истәлекләрендә урын алган фигыль формаларының кулланылыш үзенчәлеген өйрәнү ядкәрләрдә әдәби телнең нигезен билгеләү өчен әһәмиятле. Ядкәрләр телендәге фигыль формаларын галимнәребез Ф.С. Хәкимҗанов, Ф.М. Хисамова шактый тәфсилле өйрәнгән, эш барышында аларга таяндык. Төрки телләрдә фигыль сүз төркеменең һәм аның төп грамматик категорияләрен формалашуы турындагы карашлар бу өлкәгә караган башка хезмәтләрдә дә шактый эзлекле яктыртыла. Галимнәр фикеренчә, күпчелек төрки чордагы язма истәлекләрдәге кебек бу язмаларда да грамматик формалар катнаш хәлдә кулланыла. Идел буе Болгар дәүләте чорында язылган Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» пооэмасында, эпитафик язмалар нигезендә, борынгы төрки әдәби телгә хас традицион формалар белән бергә, шул чор гомумхалык сөйләм теле өчен хас тел нормаларын ачыкларга мөмкинлек бирә.

### 1.6.1. Затланышлы фигыль формалары

Затланышлы фигыльләрнең истәлекләрдә хикәяләү, боеру, теләк, шарт наклонениеләре кулланылганнар.

Хикәяләү наклонениесе. Хикәя фигыльләр әдәби истәлекләр телендә, күп төрле заман формалары булган шактый катлаулы фигыль системасын тәшкил итә. Аларны фәндә кабул ителгәнчә, өч объектив заманга туплап күрсәтергә мөмкин: үткән заман, хәзерге-киләчәк заман, киләчәк заман. Заманнар синтетик, ягъни кушымчалау һәм аналитик юл белән ясалалар.

*Хикәя фигыль. -ды/-де, -ты/-те* кушымчалы үткән заман хикәя фигыль язма истәлекләрдә гаять актив кулланылган. Билгеле (категорик) үткән заман дип йөртелә торган *-ды/-де* кушымчалы үткән заман хикәя фигыль килеп чыгышы буенча иң борынгы төрки нигез телгә нисбәтләнә һәм хәзерге барлык төрки телләрдә гамәлдә йөри. Кулланылышы буенча әлеге заман формасы бер функцияле, үткәндә сөйләүченең күз алдында булган, аның тәгаен үтәлгәнлеге сөйләүчегә мәгълүм булган эш-хәлне белдерә. Мисаллар: «Кыссаи Йосыф»: дүнә бир дүш күрдем (كورديم), дүшүм эчрә ун бир қузый күдәр идем (ا يديم), сақлар икән бирисин йауә қылдым... (قيلديم) [С.Б. 4б].

«Ана вә угыл» дастанында: йүземни чәүереп уардым (اوردوم) мән пәйгәмбәрә [С.Б. 9Б-39]; ушал дәм дөштем (دوشتم) тик айағына [10А-43]; бәлки шул йирдин турдум (توردوم) үри [10А-53]; бу дөнйага биз кәлмәдүк (كلمادك) саналум [12Б-171] һ.б.

Үткән заман хикәя фигыль үткәндә дәвамлы булган эшне белдерә («Кыссаи Йосыф» поэмасыннан үрнәкләр): бең ики йүз йыл тәмам тәғат қылдым (قيلدم) [С.Б. 9а]; «Ана вә угыл» да: бир кичә бәнем үчүн турдуң (توروننک) ул [11Б]; күтәрди (كوتاردى); кәндүзене атды (اتدى) үдә [13Б].

Эш-хәрәкәтнең бер-бер артлы эзлеклелеген белдерә. «Кыссаи Йосыф»та: сәүенүбән мән аны дирүр идем (ديرور ايديم ) Йусефи бән көрмәдим (كورمادم) һәм дәхи қандалығин белүмәдим (بلومديم), мәғаз аллаһ, хақ белүр, бән һич күрмәдим (كورماديم) [С.Б. 10б];

«Ана вә угыл» дастанында: сәвенди, үбди (سوندى اوبدى) ул икәүнең йөзин [12Б.177]; баң ауазы қулагына кермәди (كرمادى) [9Б.32]; чықдум (چقدم); күрдүм (كوردوم): ан аның көзигә [10А.51].

Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнешенең тулы парадигмасы теркәлгән.

I зат берлек санда:

«Кыссаи Йосыф»та: Йағқуб әйдер дүнә бир дүш күрдем, дүшүм эчрә ун бир қузый кӱдәр идем, сақлар икән бирисин йауә қылдым [Ф. 58.5–7]; дүшүм эчрә ағлайу үрә дордым,йа әбәти, дөшемдә он қорд күрдем [Ф. 62.34-35]; йарлы Йусеф ағлайу ардым дәйүр,сусызлықдан йаулақ зәғиф улдым дәйүр, айақларым ағырды, қалдым дәйүр [Ф. 64.9–11]; аны ағыр бәһайә сатун алдум, җөмлә малум бәһасенә фида қылдым,әдәбсезлек ул уғландан тәлим күрдем [Ф. 178.17–19); йите сөнбел дағы буғдай бирлә күрдүм,йәнә йите сөнбел дағы қоруғ күрдүм,йәнә буғдайлары күкгә учды күрдем [Ф. 194.21–23]; тәүфиқ носрәт, фәһме қуәт хақдан булдум,илһам рузи қылдуғына шакир булдум,бу арада бу китабны тәмам қылдум [Ф. 294.13–15] һ.б.

Юклыкта: Валлаһ, Йусефи бән күрмәдим һәм дәхи қандалығын белүмәдим,мәғаз аллаһ, хақ белүр, бән һич күрмәдим [Ф. 84.40–43].

«Ана вә угыл» дастанында: йүземни чәүереп мән пәйгамбәрә [Н. 59.30]; ушал дәм дөштем тик айагына [Н. 60.43]; чықдум күрдүм ананың көзигә [Н. 60.51] һ.б.

I зат күплек санда:

«Кыссаи Йосыф»та: йа баба, чуқ арадуқ,унуламыз ул арада чуқ истәдек, әғзасендән һич нәснә булумадық [Ф. 82.37–39); ун сәкез йармақ алдық, сәнең бирлә бу сатуны тәмам қылдық,җөмләмез бу сатуйа рази улдық [Ф. 96.21–23); җөмләмез бу сатуйа рази улдық,қолумызы сатмаға рәуа күрдек, унуламыз рази улуб, бети йаздык [Ф. 98.13–15] һ.б.

«Ана вә угыл»дастанында: бу дөнйага биз кәлмәдүк саналум [Н. 63:171].

II зат берлек санда:

«Кыйссаи Йосыф»та: сән йалан дүш күрдең, атамыза ул дүши сән хуб йурутдың, йалан дүшлә безләрдән сәүклү улдың [Ф. 64.5–7); ул уғланны нитә күрдең, аның тәғбир белдүгин нәчүк белдең,мөғәббирлек қылдуғин қандә күрдең [Ф. 196.13–16] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында: Бир кичә бәнем үчүн турдуң уғлуң тийү мәни имүздүң [Н. 63:154–155) һ.б.

II зат күплек сан формалары сирәк күзәтелә.

«Кыйссаи Йосыф»та: бәңа қаты душман сиз улдыңыз, нахақ бәңа ағыр җәфа сез қыйлдыңыз,ахыр бәндан җөрмү хәта нә булдыңыз [Ф. 68.5–7] һ.б.

III зат берлек санда: қәрдәшләри аны ишдеб кәйед қылды, хәсәдләри, кәйедләри ғалиб улды, җөмләсинең хатеринә ғоссә йағды

[Ф. 54.21–23]; Қәрдәшләри хатерин қуйумады, разин гизләб, айырақ сүз дәйүмәди,сиддиқ ирди, йалан сүз сүйләмәди [Ф. 56.5–7] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында: тышра чықды күрди оғыл ананың хәлин [Н. 64.191]; күтәрди кәндүзене атды удә ут эчендә қалды оғлы бирлән йәнә [Н. 64.4–5]; сәенди, үбде ул икәүнең йөзен [Н. 64.177]; баң аазы қулагына кермәди [Н. 59.32]; атды оғлан аташы анасы йүзинә [Н. 61.65] һ.б.

III зат күплек сан формалы фигыльләр актив кулланыла:

«Кыйссаи Йосыф»та: үндәйүбән Йусефи кэлтүрдиләр,ун қәрендәш йығлашуб утурдылар,җөмләси тәуазеғлиқ кэтүрдиләр [Ф. 54.36–38] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында: Нәмруд отун мәним үчүн йақтылар ул мискинни ул отқа быракдылар [Н. 63.16]; Уғланны тәә буйнындин алдылар, Сәйәсәт мәйд анына кәлтүрдиләр Ғали чағырды утун кәлтүрдиләр һәр бир е бирәр қучақ күтәрдиләр йақтылар ул утны йаулақ қаты ғазиларның күккә чықар фөрйады [Н. 62-63,132–139] һ.б.

Эпитафик язмалаларда галим Ф.С. Хәкимҗанов борынгы төрки әдәби тел традициясенең саклануын, ягъни нигез *-л* тартыгына тәмамланса, саңгырау тартыктан башланган кушымча ялгануын белдерә. Галим bol- нигезенә үткән заман фигыль формасының берничә төрле варианты ялгануын искәртә:

1)بَلطوى [t, 7, 8, 10, 25 и т. д.], بلُ طوى [t, 59] boltï

2) باطوىُ [t, 45] boltï

3) بَلطَوُى [t, 9] boltï

4) بلطِى [t, 57] boltï

5) بَلطُىّ [ǯ, 37] boltu

6)باالطو [t, 30] boltu

7) بلجي [ǯ, 22] и باالج [ǯ, 32] bolči [Хакимзянов, 1978, с. 72].

*-ды* формалы сүзләр теркәлүен дә билгели: jegerme eki jašïnda wafat boldï [90), hiǯrätqa jeti jüz jegerme segizdä erdi [64:] [Хакимзянов, 1987, с. 59].

Әдәби текстларда *-ды/-ди* кушымчалары ассимиляцияләшми, I зат берлектә һәм күплектә иренләшмәгән вариантта килә, иренләшеп килү очрагы чагыштырмача сирәк. Бу күренешне исә традицион орфографиянең халык сөйләм теле тәэсирендә, шулай ук күчереп язучыларга бәйле үзгәреше дип бәяләргә мөмкин. Текстлардагы сөйләм ситуациясенә бәйле рәвештә I зат III зат формаларының берлеге һәм күплеге теркәлгән.

Нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль истәлекләр телендә *-мыш/-миш* кушымчасы белән ясала. Тарихи формалашуы ягыннан *-мыш* формасы иң борынгы төрки әдәби телгә барып тоташа. Борынгы язма истәлекләрдә теркәлүләренә килгәндә исә, иң борынгы Орхон-Енисей язмаларында, шулай ук борынгы уйгыр, манихей язмаларында нигездә *-мыш* формасы үткәндә булган, сөйләүче үзе күрмәгән, нәтиҗәсе буенча күз алдына китергән процесслар турында хәбәр иткәндә кулланылган [Нуриева, 2007, б. 39].

Болгар чорында язылган истәлекләр теленә *-мыш* кушымчалы фигыльнең килеп керүен традицион әдәби тел тәэсире дип карыйбыз. Мәсәлән: түрт биң түрт йүз мәсҗед бина қылмыш (قلمش) имди [С.Б. 1а–4]; җәмиғ Қөран хәтасызын дүзмеш (دوزمش) имди [С.Б. 1а5]; хәқыйқәт, Йусефи ул қорд йэмеш (يمش) [С.Б. 9б149]; Соңра дура аның суы үстүн кэлмиш (كيلمش), йылан-чайан җөмлә анда мәқам дутмыш (دوتمش), хәшарәтләр җөмлә анда мәҗмуғ улмыш (اولمش) [С.Б. 8б]; Мәлик әйдүр: Зиндана ул нәчүк кермеш, нә сөч қылмыш, ушал уғлан нә ишләмеш, сақый әйдүр изәси қаза вирмеш, ун ики йыл зиндан ичрә қалмыш имди [Ф. 196.25–28] һ.б.

*-мыш* кушымчалы заман текстларда үткәндә булган вакыйгаларны тасвирлау өчен шактый иркен кулланылган, сөйләүченең үзенең күрмәгәнлеге, кешедән ишетеп сөйләү кебек мәгънәсе белдерелгән. «Кыссаи Йосыф» поэмасында Кол Гали *-мыш* формасын әсәрнең төп геройлары Йосыф, Зөләйханың үткән тормышын тасвирлау өчен иркен кулланган: қәрдәшеңез Йусеф бир дүш күрмиш (كورمش), ай, күн, ун бир йулдыз аңа сәждә қылмыш (قيلمش) атаңыз Йағқуб аны изгү йурмыш (يورمش) [С.Б. 3б/33]; Зөләйхә қолына ғашиқ улмыш, қолы мотиғ улмамыш рисва улмыш,ғәзиз дағы ул әхуали бәллү белмеш, қулун қуа чықдуғын күрмиш имди [Ф. 174.5–8] һ.б. Поэманың характерына, андагы сөйләм ситуациясенә бәйле рәвештә бу форма күбрәк III зат берлек формасы нда кулланылган, сирәк *-дүр* аффиксы белән дә килә: безә үкүш тигмешдүр рәнеж ғәна [Ф. 258.44].

Сирәгрәк *-мыш* формасы II зат берлек һәм күплек кушымчаларын ала: Йа Исраил, бу иш үзрә йаңылмыш сән,мәүлә шиддәт вирдекен йад қылмыш сән, ахир рахәт вирдүкен тәрк қылмыш сән, сәүдек уғлун Йағқубдан айырмыш сыз,фирқәт утын бәғринә йандырмыш сыз [Ф. 262.5–7]; сез ул кем, Йусефи алдамыш сыз, безим илә тәмашайа кэл, димеш сез, хәқыйқәт, үлдермәкгә қәсд қылмыш сыз, әлеңездән Йәһүдә алмыш имди [Ф. 264.21–23]; Йусеф әйдүр бир қол уғланны

сатмыш сыз, қолумызның үч ғәйбе һәм вар димиш сез, ул шарт илә бу бети не сез йазмыш сыз [Ф. 264.5–7] һ.б.

Текстта *-мыш* кушымчалы фигыль күп очракта барлык формасында кулланылган. Эшнең үтәлмәвен белдергән мисаллар чикле, бары биш очрак теркәлгән. Юклыкны белдерүнең ике төрле ясалышы урын алган: а) *-ма, -мә* кушымчасы ярдәмендә һәм ә) исем сүз төркеменә хас дәгел кисәкчәсе белән дә белдерелгән. Мисаллар: а) Йусеф әйдүр ул дүш уйлә улмамышы, йәнә ул дүш тәэвиле кәлмәмиши, ул Мисырның падишаһе улмамышы, ул әхуалдән белүрмүсиз сезләр имди[Ф. 228.25–27]; ә) җиһан ичрә сәндик бәшәр улмыш (اولمش) дәгүл, сәңа биңзәш һич кем-ирсә дуғмыш (دوغمش) дәгүл, һич кимсәнә сән сифатлу улмыш (اولمش) дәгүл [С.Б. 27а].

*-мыш* кушымчалы үткән заман «Ана вә угыл»дастаны текстында шулай ук чагыштырмача сирәк очрый, бары ике мисал теркәлгән: ул уғланны остазға вирмиш (ويرمش) ирди [9А.15]; бойорығың бирлә қылмышлар (قيلمشلار) хазир [14А.223].

Кабердаш язмаларында нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльнең *-ган, -мыш* кушымчасы ике мисалда теркәлгән: tamγačï İbrahim as-Suwari wafat bolγan; hamişa baqıj ermiş [Хакимзянов, 1987, с. 59].

*-ып/-еп* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман борынгыдан килгән әдәби тел формасы санала. Таралышы буенча әлеге форма нигездә кыпчак төркеменә караган төрки телләрдә кулланылган. *-ып/-еп* күрсәткечле заман «Кыйссаи Йосыф» поэмасында бары тик өч мәртәбә генә кабатлана, семантикасы буенча нәтиҗәле үткән заман мәгънәсен белдерә. Мисаллар: Йусеф әйдүр: хәлвәт сәрай бизәнебдер, хурлар кеби Зөләйхә дүзәнебдер, рәҗим шәйтан аздырмаға уз аныбдыр [Ф. 158.29–31].

Үткән заманның аналитик формалары вакытны белдергән нигез һәм ярдәмче фигыль *-ир* формасы белән ясала. Истәлекләр телендә ике форма: күптән үткән заман *(-ды ирде, иде, -мыш ирде, -ыб иде)* һәм тәмамланмаган үткән заман *(-ар ирде)* формалары кулланылган.

*-ды ирде/иде, -мыш ирде/иде, -ыб иде* формадагы үткән заман хикәя фигыльләре шактый сирәк күзәтелә, аларның мәгънәләре аерымланмый, әсәрдә өч форма да икенче бер эштән алда булган процессны белдерә. Мисаллар:

*-ды иде:* бән зинданә вардым иде (ژاردم يدى), зиндан ичрә бир ғәҗәб дүш күрдем иде (كوردم يدى), тәғбирени ул уғландан сурдым иде (صوردم يدى) [С.Б. 196–658]; Үдә микән бән бир сақынч қылдым иде (قالدوم ايدى), бу иш эчрә сезгә гөман қылдым иде (قالدوم ايدى) [С.Б. 68] һ.б.

*-мыш иде:* ул икеси кәрамәтлү қупмыш иде (قوپمش), ғәзиз анда хазир иде, аны күрди, Зөләйхәнең биңзе йаман дүнмиш иде, сизенде, анлардан әхуәл сурды [Ф. 170.21–23]; Кәнғанда дормыш идүм, бир вақыт да ул мәқами күрмеш идем, кечеклекдә анда тәлим дормыш идем, бу тели бән үгрәндем дәйүр имди [Ф. 234.17–20] һ.б.

«Ана вә угыл»: дөнйасын ахирәткә сатмыш иде (ساتمش ايدى) [8Б.3]; изги ат бирлән изгү нам дотмыш иде (دوتمش ايدى) [8 Б.4]; ол хатунның халәли өлмиш (اولمش) иде [9А.13]; аның бирәр уланчығы қалмыш (قلمش ايردى) ирди [9А.14].

*-ыб иде, -ыб дурур:* бу кичә бир дүш күрдем, дүшем эчрә Кәнғана варыб идем[Ф. 88.5–6]; Шамдан йаңа қапуда кәлеб дурыр, кемни күрсә, хәбәр сурар һәм йалуарыр[Ф. 232.41]. Күптән үткән заманның аналитик формаларын кулланууда кайбер үзенчәлекләр күзәтелә.

*-мыш иде* формасы нәтиҗәле үткән заман мәгънәсен дә белдерә ала: ул қойу ашнудан қалмыш иде, аны ушал Ғад кәфир қазмыш иде, дөбе дирән, суы йаулақ ачы иде [Ф. 72.1–3]; Ул зәманда бир заһид қубмыш (قوبمش) иде, китаб эчрә Йусеф васфин белмеш (بيلمش) иде, қамулара аны мәғлум қылмыш (قيلمش) иде [С.Б. 8б; Ф. 72.9–12].

*-ды иде* кушымчалы фигыль автор сөйләмендә генә кулланыла, шуңа күрә аның бары I зат берлек формасы теркәлгән. Зат кушымчалары ярдәмче фигыльгә түгел, ә төп фигыльгә ялгана: вардым иде, бақдым иде, қылдым иде һ.б.

*-ыб иде* формалы фигыльләрдә исә зат кушымчалары ярдәмче фигыльгә ялгана: варыб идем, вирүб иде, виреб иде, I зат һәм III зат берлектә очрый. *-мыш иде* формасының текстта бары III зат берлек санда килүе күзәтелде.

Тәмамланмаган үткән заман *-ар иде, -әр иде, -ыр иде, -ур иде* формаларында теркәлгән. Бу форма гадәттә, тәмамланмаган, дәвамлы эш-хәлләрне белдерә. Мәгънәсенә килгәндә, үткәннең билгеле вакытына караган, тәмамланмаган эш-хәлләрне белдерү өчен кулланылуы күзәтелә: Йағқуб йәстү намазын қылур ирди (قيلور ايرد ى) [С.Б. 9а.144]; җәмален бирин бирин әйтүр ирди [Ф. 160.3]; Зөләйхә бир күн йатыб уйур ирди [Ф. 152.1] һ.б.

Бу форма дастанда эшнең дәвамлылыгын, гадәти булуын белдерү өчен кулланыла: иш бирлә йүрүр ирди (يوروراير دى) ул фәқир [8Б.5], хәзрәти Илйас кәлүр ирди (كالور ايردى) қатына [8Б.9], күнәшә ухшар иде (وحشار ايدى) аның йүзи [9А.17].

Кабатлаулы эш-хәлләрне белдерү мәгънәсе белән дә кулланыла: Йусеф сиддиқ бәнүм қолум улур иди,ғобудийәт самәдына қылур ирди,

мөдам самәд әмрилә йүрер ирди [Ф. 212.33–35]; қоллары күрәчәк хуш дутар идүм, ғәрибләри күрәйәчәк ағлар идүм, қайғулары күрәйәчәк йығлар идүм [Ф. 248.5–7] һ.б.

Әмма *-ар иде* формасы аерым очракларда үткәндә булган, кабатланмаган эш-хәлләрне белдереп килә: бән дағи бир дөш күрдем (كوردم), башымә чоқ үтмәкләр күтәрер идүм (كوتارر يدم), йите симез сығыр күрдем, җөмләсинең арқасына бенәр ирдем, бирисиндән бирисинә кэчәр ирдүм [Ф. 194.13–15] һ.б.

Сирәгрәк тәмамланмаган үткән заман мәгънәсен *-ыр ирмеш* формасы да белдереп килә ала: дөнйа эчрә бонча дәүләт улур ирмеш (ايرمش), шөйлә икән, бута табу қылур ирмеш (ايرمش) ул Зөләйха аның қызи улур имеш [С.Б. 10б–368]. Поэмада чагыштырмача сирәк үткәнгә караган теләк мәгънәсе очрый: сизиң атаңызы ағырладым, йухса бән сези буйлә қоймаз идем, җөмләңези ғазаб бирлә үлдерер идем.

Әсәрнең эчтәлегенә бәйле бу формалар күбрәк III зат берлек санда кулланылган, сирәгрәк шулай ук I зат формалары да очрый, 1 төр зат кушымчаларын ала. I затта кулланылышы: Мисыр эчрә улу хатун улур идүм, адәмләргә сәрвәрлекни қылур ирдүм, андан бирү сәни мәғбуд билүр ирдүм [Ф. 212.29–31]; күкдән кушлар инәр ирде күрәр ирдим [Ф. 146:3] һ.б.

III затта кулланылышы: Йусеф сиддиқ бәнүм қолум улур иди, ғобудийәт самәдына қылур ирди, мөдам самәд әмрилә йүрер ирди [Ф. 212.33–35]; Халиқ бәни сәнең үчүн сақлар иди, бәңа биңзәр бир див қызы кәлүр иди [Ф. 218.2–3] һ.б.

*-р ирди* формасындагы аналитик үткән заман хикәя фигыль хәзерге татар әдәби телендәге *-а иде* формасының синтагматик, ягъни үткәндәге гадәти эшләрне белдерә торган мәгънәсе белән кулланыла. Шуның белән бергә, *-р иде* формасы кыйссада алга таба сөйләнәчәк хәлләргә фон булып тора, тәмамланмаган эш-хәлләрне белдерә, хикәят сөйләүченең карашы буларак аңлашыла.

Хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыль борынгы төрки әдәби телдән үк килгән гомумтөрки фигыль формасы, өйрәнелә торган чорда түбәндәге формаларда чагылыш таба: *-р, -ар/-әр, -ур/-үр, -ыр/-ир.* Традицион әдәби тел үрнәкләрендә һәм хәзерге күпчелек төрки телләрдә нигездә хәзерге-киләчәк заман мәгънәсендә кулланыла. Хәзерге татар телендә исә әлеге заман формасы күбрәк киләчәктә булачак эшне белдерә.

*-ыр/-ер, -ар/-әр* кушымчалы заманның ике мәгънәдә, ягъни хәзерге-киләчәк һәм шулай ук киләчәк заман мәгънәләрендә кулла-

нылышы борынгыдан килгән үзенчәлек булып тора. «Кыссаи Йосыф» поэмасында һәр строфада диярлек *-р, -ар/-әр, -ур/-үр, -ыр/-ир* күрсәткече кабатлана. Мәсәлән, поэманың 2 фасылында (140 юл) авторның фигыльләрне 82 тапкыр файдалануын билгеләргә кирәк һәм алартөрле заман мәгънәсендә килгән.

1) Хәзерге заманга караган, ягъни сөйләү моментында башкарыла торган эш яки хәлне белдерә: Йусеф аны ишдеб, қанын ағлар хәсрәт уды әчин йағар, бәғрин дағлар; ағлар икән һәм кирү дәстүр деләр [Ф. 98.13–15]; аны бездән ики артуқ сәүәр имди (سوار) [С.Б. 4б]; анасының сағ көзи шул дәм чықар ким анасының күңүлүн йықар [Н. 61.67–68] һ.б.

2) Даими, кабатланган эш-хәлләрне белдерә. «Кыссаи Йосыф»тан мисаллар: атамыз аны бездән артуқ сәүәр, аның йүзин күрмәкгә йаулақ ауар, инҗи вирсә, бездән аңа артық вирүр, аны бездән ики артуқ сәүәр имди [Ф. 56.25–28]; Йусеф әйдүр Халиқдан бән қурқармән (قورقارمًا),кәндүземи мәгсийәдән бән сақлармән (ساقلارمًا), ахирәт хален аңуб сақынурмән (ساقينورمًا) [С.Б. 40а] һ.б.

3) Киләчәк заман төсмерен белдереп килә. «Кыссаи Йосыф» тан үрнәкләр: ғад қойусы тигрәсендә йүрдең исә, бир шәриф қол әлеңә керәр имди [Ф. 88.23–24]; қәрдәшләри үфкәсендән сақлар имди (سقلار) [С.Б. 8а] һ.б.

Хәзерге-киләчәк заманның зат-сан белән төрләнеш парадигмасы теркәлгән.

I зат берлектә «Кыссаи Йосыф» поэмасында фигыль формасына *-мән,* сирәгрәк *-вән, -ым* кушымчалары ялгана: сәңа биңзәр һич кимсәнә бәлүмәзмән (بلوماذمًا), бир ләхзә сәнсез қәрар қылумазмән (قيلومذمًا), сәндән айру бирәр дәм булумазмән (بولوماذمًا) [С.Б.38б]; бу әхуалең нитәлекин безгә сурар (صورار) [С.Б. 35.469] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында исә I зат берлек *-ам, -мән* кушымчалары ярдәмендә белдерелә: ут эчендә туташ бән йанарам (ينارام) чықамазам түрт йанка бақарам (باقارام) [Н. 63.150–151]; йалбарурмән йа анам җаным сәңа [Н. 61.93] һ.б.

II зат берлектә *-р-сән:* йә қызым, нә варырсән (وروررسن), нә мәғнәдән ағлайу йүгәрүрсән (يوگرورسن), тәғҗил бирлә Йусефә йәтәрмүсән (يتارموسن) [С.Б.] нә ағлар сән, күңелеңдә нә кэчәр, нә теләйүрсән, дүшең эчрә нә күрүб арзулар сән [Ф. 130.1–3] һ.б.

«Ана вә угыл»дастанында: җанумны утқа йакарсән (ياقارشن); бәни [Н. 60.37]; кем бир қапуга чықасыз (چقاسز) [Н. 64.186] һ.б.

III зат берлектә: Йосыф дисә, күзләрендән қанлар ақар,фирқәт удының хәсрәти бәғрен йақар,висалеңә өмид дутар, күрмәк умар, қаушмақдин өмидин кэсмәз имди [Ф. 246.9–12] һ.б.

«Ана вә угыл»дастанында: анасының сағ көзи шул дәм чықар ким анасының күңүлүн йықар [Н. 61.68–69]; үлтерерләр кисәрләр әлеми [Н. 61.91] һ.б.

«Кыссаи Йосыф» поэмасында еш кулланыла торган *әйдер* сүзформаның конкрет бер генә заман төшенчәсен белдермәве күренә, процесс сөйләү моментында булырга яки үткәнгә карарга мөмкин. Мисаллар: Йағқуб әйдер ул иш уйлә улмаз имеш (اولمز ايمش), Йусефем сезнең илә вармаз ирмеш (وارماز ايرمش), ул иши һәм үзем рәуа күрмәз имеш (كورمزا يمش) [С.Б. 5а.52]; Йәһүдә әйтүр бу эшеңез рәуа улмаз (اولماز], қәрендәш қәрендәшни һич өлдермәз (اولدورماز), муны қылган халиқдан рәхәт булмаз (بولماز) [С.Б. 8а.98] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында: уғлан әйтүр (ايتور): «Йә Рәсулуллаһ» [10А–45]; анасы әйтүр (ايتور) әй уғлум чук сөйләмәй [10А.55] һ.б.

Юклык аспекты *-ма-з/-мә-з* формасында килә.

«Кыссаи Йосыф»тан мисаллар: солтан лардин чуқ теләрләр, һәргиз вармаз (وارماز), айруқ лары һич бикенмәз, күңел вирмәз (ويرماز), хатерендән ул сәни һич кидәрмәз (كيدارماز) [С.Б. 22а]; һәр кем бәни теләйүрсә тәләйүрмән (تلايورمًا), һәзар чәндан арзу бирлә эстәйүрмән (ايستايورمًا), малум мөлкүм җөмлә фида әйләйүрвән (ايلايورمًا) [С.Б. 29б.96] һ.б.

«Кыссаи Йосыф» поэмасында фигыльдә мөмкин түгеллек *-а/-ә, -у* кушымчасы алган нигезгә *-ма/-мә* юклык кушымчасы ялганып ясала: атамыза йалан дәхи улумазыз (اولومازز), сәни кирү атамыза илтүмәзез (ايلتومازمز), ошбу ишә һич тәдбир улумазыз (اولومازز) [С.Б. 18б] һ.б.

Хәзерге-киләчәк заманның сорау кисәкчәсе белән кулланылышына мисаллар сирәк очрый: әй, дәриға, ғәзиз анам, йатурмусән (ياتورموسن), бу хәл эчрә бәнүм халем белүрмүсән (بلورموسن), бақыб бәни бу хәл үзрә күрәрмүсән (كورارموسن) [С.Б. 19б].

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, бу чор әдәби телендә *-р* формалы заманның семантикасында, борынгы төрки әдәби телдәгечә, күп төрле заман мәгънәсенә ия булуын күрәбез.

*-а/-ә* кушымчалы хикәя фигыль истәлекләр телендә хәзерге һәм киләчәк заман мәгънәләрен белдерү өчен кулланылган. Хәзерге төрки телләрдә, угыз төркеменә кергән телләрдән башка, бу форма хикәяләү наклонениесенә керә һәм хәзерге заман күрсәткече булып

тора. Э.А. Грунина *-а* формалы фигыльләрнең XIII–XIV гасыр язма истәлекләрендә заман күрсәткечләре булуын билгели [Грунина, 1966, с. 84–89]. А.Н. Кононов әлеге форманың киләчәктә ният ителгән процессны белдерүен күрсәтә [Кононов, 1980, с. 188]. Борынгы төрки рун язулы текстларда *-а* кушымчалы хикәя фигыль очрамый.

«Кыйссаи Йосыф» текстында *-а* күрсәткечле фигыль мәгънә киңлеге белән аерылып тора, шулай да киләчәк заманны белдерү зур урын алып тора.

1. Үтәләчәгенә шик булмаган киләчәк заманны белдерә: өмиддер кем мәүлә сәңа вирә мөлкәт, фазлы бирлә рузи қыла үкүш ниғмәт, қәрдәшләриң җөмләси қыла хезмәт, ун бир иси сәңа хезмәт қыла имди [Ф. 52.17–20]; йиде йыл учыз ула, әлуан дөрлү ниғмәт илә ғаләм дула, андан соңра қызлық ула, муңлу ула, йиде йыл ғәзим дарлық ула имди [Ф. 198.17–20] һ.б.

Поэмада *-а* күрсәткечле фигыльләрнең киләчәк заман төсмере төрле юрауларга бәйле эш-хәлләрне белдергәндә файдаланылган. Эш-хәлләрнең сөйләү моментында үтәлү, яки даими кабатланган процессны белдереп килү очрагы шактый аз күзәтелә: йухса бән сөҗүд ичрә қылам зари, сезгә ғәзим афәт вирә изим бары,мөстәҗаб ул қыла барчә доғалары [Ф. 84.17–19]; ошбу ишни әй қәрдәшләр сез қыласыз бу иш илә атамыза ғақ уласыз байық мәүлә рәхмәтендән айруласыз рөҗуғ идүб истиғфар қылың имди [Ф. 70.1–3] һ.б.

Җөмләдә *-р* һәм *-а* кушымчаларының вариатив кулланылыш очраклары теркәлгән: мәхрүм мәхзүн қуйасыз Исраили, хәсәд бирлә күйдерерсиз ул зәлили [Ф. 66.17–18].

Контекстта *-а* кушымчалы фигыльнең шарт мәгънәсен белдерү өчен кулланылу очрагы күзәтелде. Чагыштыр: Кәрәкмәз кем ошбу әсрар заһир ула, қәрдәшләрең бу мәғнәдән хәбәр биләֹ,бу иш әчрә анлар сәңа хәсәд қыла, ибтидаси безә михнәт ула имди [Ф. 54.9–12]

*-а* кушымчалы фигыльнең зат-сан белән төрләнеш парадигмасында шактый үзенчәлекләр күзәтелә. I зат берлектә кушымчаларның кыскарган төре урын ала. Мисаллар: аһ дәриғә, бән қоллық нәтә қылам, мөдам кәфир қол луғында нәтә улам, улуларым, имди сези қанда күрәм [Ф. 100.6–27] һ.б.

I зат күплектә угыз телләренә хас *-уз/-үз* кушымчасын алып төрләнә: Анлар әйдүр Йусефи без сақлайауыз, қәрдәшемез қорддан қачан қапдырауыз, ғәләм қордын қырауыз, үлдерәүез вә Аллаһи, Йусеф үчүн дирләр имди [Ф. 58:9–14].

Текстта *-а-м* I зат берлек сан күплек мәгънәсен белдереп килү очрагы теркәлгән: соңра дүнеб хәтамызға тәүбә қылам, қылдығымыз мәғсийәтгә мөқыйр кәләм, андан соңра мөдам тағәт үзә булам, тәүбәмези тәүваб қабул қыла имди [Ф. 60.13–16].

II зат берлектә зат кушымчасының тулы варианты *-сән, -сын* кулланылган. Мисаллар: Ул мәғнәдән улуғлықға дигенәсен, халиқның, бирлигинә инана сен, көфер ширкәт михнәтендән қуртуласын, дөнйа ахирәт дәүләти күрнүр имди [Ф. 90.1–4].

«Ана вә угыл»: изләйәсән уғлыны табмайасән (تابمايسن) [11А–119];

*-а* күрсәткечле фигыльнең II зат күплек саны *-сыз/-сез* кушымчалары белән ясалган. Мисаллар: әманәтдер Йусефи сақлайасыз, нәүбәтләшү игнеңезгә көтәрәсиз, җөмләңез игү тимарлар қыласыз бу сүз илә Йусефи күндерер имди [Ф. 60.37–40].

III затның берлек саны кушымчасыз (Ø) гына теркәлгән: Ғаләм эчрә сәнең адың мәшһүр ула, Мәшриқ Мәғриб улулары сәни билә, қыйәмәтә дикен адың бақи қала [Ф. 52.21–23] һ.б.

*-а* формалы фигыльнең төрләнеш парадигмасы түбәндәгечә чагыла:

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | -а -м | -а -уыз, -үез |
| II зат | -а -сын, -син | -а -сыз, -сиз |
| III зат | -а – Ø | – |

*-йур/-йүр* кушымчалы фигыльнең текстта бары сөйләп торган моментта үтәлгән эш-хәлләрне белдергән мәгънәсе теркәлгән. *-йур/-йүр* кушымчалы фигыльләр чагыштырмача сирәк, бары 18 сүзформада теркәлгән.

Мисаллар: Атасы сурар, әйдер нә ағларсан,күңелеңдә нә кәчәр, нә тиләйүрсән, дүшең эчрә нә күрүб арзуларсан [Ф. 130.1–3]; Сәүенди морадыма ирдем дәйүр, ғәзиз Мисыр җәмалени күрәм дәйүр, җөмлә малум дәрвишләрә вирәм дәйүр [Ф. 134.21–23] һ.б.

Угыз төркеменә караган күпчелек төрки телләрдәге кебек үк, *-йур* кушымчалы заман беренче, ягъни тулы төр зат-сан кушымчаларын алып төрләнә.

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | -йүр-мән, әйлә-йүр-вән | -йүр-мез |
| II зат | -йүр-сән | – |
| III зат | дә-йүр-Ø | – |

Сөйләү моментыннан соң һичшиксез үтәләчәк эш-хәлләрне белдерү өчен поэмада *-дачи, -дәчи* аффикслы киләчәк заман хикәя фигыль формасы шактый еш кулланыла. Борынгы төрки телдә *-дачы* кушымчасы киләчәк заман хикәя фигыль һәм сыйфат фигыль ясауда катнашкан, беренче тапкыр әлеге кушымча Орхон текстларында күзәтелә, «р, л, н» тартыкларына тәмамланган нигезгә саңгырау – *-тачы/-тәчи,* сузыкларга һәм калган тартыкларга яңгырау *-дачы/-дәчи* кушымчалары ялгану очраклары теркәлгән [Нуриева, 2007, б. 39]. Орхон язмаларында әлеге кушымчаның төрле функцияләрдә кулланылуы күзәтелә, күп очракта сөйләү моментыннан соң үтәләчәк эш-хәлләрне белдереп, киләчәк заман хикәя фигыль булып килә. Борынгы язма истәлекләрдә күп төрле функцияләрдә кулланылган бу форма поэмада хәбәр позициясендә кулланыла, сөйләү моментыннан соң булачак эшне белдерә: нөбүввәт рисаләт булдачы сән (بولداچی سًا), һәм мәмләкәт ийәси улдачы сән (اولداچی سًا), рахәтлеғә бәшарәт булдачы сән (بولداچی سًا) [С.Б. 3а] һ.б.

*-дачы* кушымчалы фигыльнең зат-сан белән төрләнеш парадигмасында берлек сан формалары урын алган. Мисаллар:

I зат берлектә *-вән* кушымчасы урын ала: бән сезгә мөдам хезмәт қылдачы вән, сез кидәнчә тәпуңызда улдачы вән,сезни күрсәм, үкүш тәшриф улдачы вән [Ф. 226.1–3] һ.б.

II зат берлектә зат кушымчасы *-сән* шул чор традицион орфография таләпләре буенча зат алмашлыгына аваздаш хәлдә язылган: Ул қулы учуз сатун алдачы сән (الداچی سن), аны сатыб, үкүш ниғмәт болдачы сәң (بولداچی سن), мөлек вә дәүләт ийәси болдачы сән (بولداچی سن) [С.Б.11а] һ.б.

III затның берлек саны кушымчасыз гына теркәлгән: Мондан соңра бәңа тимар кем қылдачы (قیلداچی), ағлар исәм, күзим йәшин кем силдәчи (سیلداچی), қайғылу үземмә кем иш болдачы (بولداچی) [С.Б.18а] һ.б.

Поэмада *-дачы* формасының III зат берлек санында *-дачидур* варианты да теркәлгән, ярдәмче фигыль *турур* кыскарып, аффикска әйләнгән: Йети күзләр күрмәз улуб солдачыдыр (سولداچیدور); Хәсудләри хезмәтинә кәлдәчидүр (کیلداچیدور), йаулақ улуғ шәремсар улдачыдур (اولداچیدور), пошиманлық нидамәт улдачыдур (اولداچیدور) [С.Б. 9б].

Борынгы төрки һәм урта төрки чорда иҗат ителгән әсәрләрнең телендә күп функцияле, ул контекстта аергыч функциясендә, исемләшкән хәлдә һәм киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсендә килгән *-дачы/-дәче, -тачы/-тәче* формасы соңрак чорда язылган истәлекләр телендә кулланылмаган. Мәҗдут Мансуроглу фикеренчә, бу кушымча

тар бер заман – борынгы төрки чордан урта гасыр язма истәлекләре теле өчен генә хас булып, төрки телләрдә кулланылыштан төшеп калган архаик форма. Бары тик татар теленең кайбер сөйләшләрендә генә *-дачы* кушымчасы сакланып калган, ди галим Мәҗдүт Мансуроглы [Mansuroğlu, 1956, s. 105–108]. Ә.Р. Тенишев бу күрсәткечнең караимнар һәм алтай төркиләре телендә очравын күрсәтә. Алтай төркиләрендә *алдачы* сүзе «үлем фәрештәсе, явыз рух», караимнарда *билдәчи* сүзе «белгеч, галим» мәгънәләрендә сакланган [Тенишев, 1998, с. 468]. Төрек галиме Е. Алкая борынгы төрки истәлекләрендә актив кулланылышта булган әлеге кушымчаның татар теленең мишәр диалектында гына саклануын, күп функциягә ия булуын дәлилли [Алкая, 2014, с. 39–47].

Сирәгрәк очракларда катгый киләчәк заман мәгънәсен белдерү өчен *-ысар/-есәр* кушымчалы фигыль файдаланыла. Күпчелек тюрколог галимнәр әлеге форманың угыз телләре өчен хас булуын, XIII–XV гасырларда Кече һәм Урта Азия ареалларында язылган ядкәрләр телендә актив кулланылышын билгелиләр. «Форма *-ысар*, выступающая только в финитной позиции, зафиксированы в памятниках малоазиатского и среднеазиатского ареалов в памятниках XIII–XV веков с достаточной частотностью. В последующие периоды ее употребление идет на убыль и в турецких памятниках XV–XVI вв. Она употребляется спорадически» [Грунина, 1983, с. 170]. Татар галиме М. Нигъмәтуллов *-ысар* формалы фигыльләрнең иске татар әдәби ядкәрләр телендә кулланылышын өйрәнеп, XVIII–XIX язучыларының текстларында *-ысар* формасының чикле кулланылуын күрсәтә, традициянең өзелми саклануын Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы тәэсирендә күрә: «Эта форма встречается по одному разу в списках Хибатуллы Салихова (сәвисәр), Абдульманыха Каргалый (кәрисәрме), Габделжаббар Кандалый (калыйсардыр). Эпизодичность употребления формы на *-ысар* говорит о том, что к этому времени она стала архаичной. Активность ее употребления была несколько выше в поэме Кул Гали «Кыйсса-и Йусуф» (4–5 случаев употребления); татарские поэты, видимо, как раз под влиянием этой поэмы и применяли данную форму» [Нигматуллов, 1991, с. 53].

Болгар чоры язма истәлекләреннән бары Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында *-ысар* формалы киләчәк заманның кулланылышына ун сүзформа теркәлгән. I зат берлектә *-мән,* II зат берлектә *-сән* зат кушымчасы шул чор традицион орфография таләпләре буенча зат алмашлыгына аваздаш хәлдә язылган. Мисаллар:

I зат берлектә: мундин соңра хикмәт таба кәчисәрмән (كيچيسارمًا), гөл вә рәйхан, дөррү мәрҗан сачисәрмән (ساچسارمًا), Йусеф нәби әхуалени ачусар мән (اچوسرمًا) [С.Б. 2а]; сезнең бирәр әлеңезе кәсисәрмен,җөмләңезнең буйынындан асысармын,барчаңызны сәйасәтлә үлдерәрмен [Ф. 264.29–30] һ.б.

II зат берлектә: Мисыр ичрә падишаһ улисәрсән (اوليسارسًا), Зөләйхәйә ғәкде никах идесәрсән (ايديسرسًا) [С.Б. 41а].

Истәлекләрдә теркәлгән хикәя фигыльләрне шул рәвешле күзәтеп чыгу, фигыльләр кулланылышының шактый үзенчәлекле картинасын ачып бирә. Күренгәнчә, бу чорда әле борынгы төрки әдәби традиция шактый тотрыклы саклана. Әдәби текстлар теленә үтеп кергән угыз тел үзенчәлекләре чагылыш таба.

*Боерык фигыль.* Боеру мәгънәсен белдерү өчен истәлекләр телендә боеру наклонениесе фигыльләре килә, традицион формалардан II затка боеру, әмер бирү, йомшак үтенү өчен *-ғыл/-гил, -ың/-иң* күрсәткечле фигыльләр зур урын алып тора, кушымчасыз варианты чагыштырмача сирәк очрый. Чагыштыр: айғыл (6 мәртәбә теркәлгән): ай күн ун бир йулдузларга айғыл [Ф. 74.31] ул оғланны аз бәһайә сатун алғыл [Ф. 90.19] һ.б.; тәғҗил варғыл сиддықым өгүтләгил [Ф. 168.22]; тәһдид қылғыл қорқытғыл өгүтләгил [Ф. 170.30] һ.б.

Нуль формалы боерык фигыль формалары текстта бары 18 мисалда кулланылган: Йусефең ағыры алтун дилә [Ф. 140.23]; бу иш сәңа рәуа дәгел йүз дүндүр чық [Ф. 168.31]; бу әхуалең тәфсыйлен сурма имди [Ф. 126.12] Йусеф әйдүр йа Зөләйхә сүзем дыңла [Ф. 162.33] һ.б.

II зат берлек сан күрсәткечләрен куллануда мәгънә аермасы күзәтелми: безүмилә тәмашайа кил [Ф. 58.23]; Бу мөбарәк уғланчықны сақла имди [Ф. 146.24]; қамулардан бу сириңи сақла имди [Ф. 142.20]; бу иш сәңа рәуа дәгел йүз дөндүр чық [Ф. 168.31] ~ урғанына йабышғыл тышра чықғыл [Ф. 92.14] һ.б.

Контекстка бәйле боерык фигыль боеру, эш кушу, йомыш тапшыру, сорау, үтенү кебек мәгънә төсмерләрен ала. Күзәтүләрдән күренгәнчә, алар формаль күрсәткечкә бәйле түгел. Мисаллар:

а) боеру эш кушу, йомыш тапшыру мәгънәсен белдерелә. «Кыссаи Йосыф»тан мисаллар: Җәбраил әйдер халә хазир үрә дорғыл (دورغيل) йабышғыл тышра чықғыл (چقغيل) нә бәһайә сатылурсән көзиң көргил (كورغيل) [С.Б. 12а]; фәһем қыл андишә қыл анларә бақ [Ф. 168.39] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында: ишит (ايشت) имди падишаһка ни қыла [14А-215] һ.б.;

ә) боерык фигыль еш кына йомшак боеру, сорау, үтенү кебек мәгънә төсмерләре ала. «Кыссаи Йосыф» әсәреннән үрнәкләр: вәләкин әманәтдер, җаным уғул (اوغول) бу дүшеңни һич кимсәгә сән әйтмәгил (ايتماغيل), адәмиләр кинәсендән ки сақланғыл (سقلاغل) [С.Б. 3б]; әтрафендә будақлары әлуан (الوان) улсун, йимешләре әлуан (الوان) дөрлү улсун имди [С.Б. 35б] һ.б.

«Ана вә угыл» дастанында: абдәст алуб намазыңа барсана (بارسنا) [9А.35] һ.б.

II зат боерык фигыльнең күплек санын *-ң, -ың, -ең* кушымачасы белән белдерү эзлекле саклана, *-ыңыз/-иңиз* формасы сирәк мисалларда теркәлгән: Тәңридән қурқың, батил ғәмәл қылмаң (قيلمانک), ахирәтдә вәбалдүр, ғаси улмаң (اولمانک), уҗмах виреб, тәмуғ утын сатун алмаң (المانک) [С.Б. 8а.99]; улдур бәнүм хаҗәтем, бәллү билиң (بيلنک), сезләр аны бәнем үчүн сатун алуң (الونک), җөмлә малум аның үчүн фида әйләң (ايلانک) [С.Б. 31а.423] һ.б.

II зат боерык фигыльнең *-ыңыз/-иңиз* күплек саны кушымчасы сирәк мисалларда теркәлгән: мәйданыны бизәңез [Ф. 138.14]; Рауил әйдүр виреңез миннәт илә [Ф. 92.41] һ.б.

*-ың/-иң* формасы аерым очракларда II зат берлек сан мәгънәсендә кулланылган: бәйан билгил: сән бәнең, бән сәнеңвән,

бәндән үзгә һич кемсәни сән булуманң,

бәнем ғишқым хатереңдән сән салуманң

бәндән үзгә һич кемсәгә бақмаң имди [Ф. 130.26-30].

III зат берлек санындагы боерык фигыль *-сун/-сүн,* ә күплек саны *-сунлар/-сүнләр* кушымчасы белән белдерелә: безүмилә Йусефең бөйлә варсун (وارسون) қой қатында безем илә бөйлә йүрсүн (يورسون) фәһме артсун, хатери рәүшан улсун (اولسون) [С.Б.4б]; аның әчин йопар бирлә бизәсүнләр [Ф. 154.45]; бизәсүнләр җөмлә Йусеф сурәтени [Ф. 156.3] һ.б.

«Ана вә угыл» мисалында: харам улсун (اولسون) әмизгән сүтим сәңа [4-97], рәхмәт әйләсен (ايلاسن) [6.152], уғлан үчүн җанымыз улсын (اولسن) фида [12Б-174] һ.б.

Каберташ язмаларында III зат берлек сан формасы гына теркәлгән: Tägalä rähmät qïlsun [8]; Täŋri rähmäte berlä sewendürsün [64] [Хакимзянов, 1987, с. 60].

Фигыльдә эш-хәлнең үтәлмәве *-ма/-мә* кушымчасы ярдәмендә белдерелә: айлар әйдүр бу сүзни бәна аймагыл [Ф. 4.29]; имди боны өлдермәң йэтүрмәң дир [Ф. 70.25] һ.б.

Истәлекләр телендә боеру наклонениеясенең II, III зат формалары теркәлгән, грамматик күрсәткечләре борынгы төрки язма традиция белән уртаклык булуны күрсәтә.

*Теләк фигыль.* Теләк наклонениесе I зат берлек һәм күплектә теркәлгән, күпчелек очракта *-айын/-әйен* кушымчасы белән белдерелә, *-айым/-әйем* формасы аз санда күзәтелде. Гарәп графикасында язылыш зат күрсәткече алдындагы әлифнең яки фәтхәнең язылу-язылмавы белән, сузыкның күрсәтелүе-күрсәтелмәве белән аерымлана. Мисаллар: ққуйыңыз бән дүшәйен, тәлим йылғы хәсрәтемә қауышайын, фирақ хәлен әхуален сурашайын [Ф. 138.29–31]; Йәһүдә әйдүр Хөфийә илә бән варайын, әйбәтилә анлара бән чағырайын, Ибне Йәминне бән андан чықарайын [Ф. 252.37–39]; Йусеф әйдүр. Иләһи, бән нә қылайын, бу михнәт дән имде нитә қуртулайын,бу залимдән қуртулмаға нә қылайын [Ф. 104.41–43]; дәстүр виргел, кирү йәнә бән варайын,улуларымны туйанча бән күрәйем [Ф. 98.21–24] һ.б.

«Кыссаи Йосыф» поэмасында I зат күплек формасы *-әлүм, -алум* күбесенчә персонажлар сөйләмендә кулланылган: Йусефи без қатумыза үндәйәлүм[اونداياLوم], нә дүш күрмеш сурайалум, изләйәлүм (ايزلاياLوم), аңа лаиқ рәййе тәдбир әйләйәлүм (ايلاياLوم) [С.Б.4а]; Йусеф әйдүр сәңа әхуәл сөйләйәлүм,кем идегүм сәңа иғләм әйләйәлүм,вәләкин ул шарт илә белдерәлүм [Ф. 142.17-19]; йазуқымны анлардан бән диләйәлүм видағ қылыб айрылалум безләр имди»[Ф. 98.21–24] һ.б.

«Ана вә угыл»: кәлмәдем кем бән сәңа күч әйләйүм (ايلايوم) [11А.123); күплек сан *-алум* формасы белән ясала: бу дөнйага биз кәлмәдүк саналум.

Боеру мәгънәсен белдерү өчен «Кыссаи Йосыф» поэмасында угыз телләре өчен хас *-а/-ә* кушымчалы теләк фигыль дә кулланыла: Йусефи без сақлайауыз (سقلاياوز), Қәрдәшемез қорддан қачан қапдарауыз (قابدوراوز) ғаләм қордин қырауыз, үлдерәүез (اولدوروز) [С.Б. 4б–51]; атасына хәқыйқәтдә бән көстәрәм,дәүләтин һәм мөлкәтин бән артдырам [Ф. 78.13–15] һ.б.

Теләк модальлеген белдерүдә борынгы төрки әдәби тел өчен хас формалар һәм *-а/-ә* кушымчалы угыз телләренә хас кушымчалар урын алган.

*Шарт фигыль.* Шарт фигыль язма истәлекләрдә күпчелек төрки телләрдәге кебек *-са/-сә* кушымчасы белән ясала, икенче бер эшнең үтәлүе өчен кирәкле шарт мәгънәсен белдерә: башларына дуқынса мәжрух әйләр,тәнләринә дуқынса мәғйуб әйләр [Ф. 106.25–26] һ.б.

I зат берлек сан: бән киру̇ варсам, дәсту̇р вирсәң, ул сәрайға киру̇ керсәм, һәмишә ул нәқышларны ку̇рә дурсам [Ф. 242.28–29]; бән сатылур қул олсам, диденқми [Ф. 92.7] һ.б. Аерым очракларда I зат берлек сан белән төрләнгән фигыль янында зат алмашлыклары да кулланыла. Мән аны кәфен сарыб, гу̇р қылсам мән,у̇стинә бир мөнәққәш дар қылсам мән,кәнду̇зем Йусефә йар улсам мән бақи ғөмрим аның у̇зрә кәчсу̇н имди [Ф. 82.33–37] һ.б.

I зат ку̇плек сан: дағы аны йаулақ сәу̇әр иду̇к, ку̇рмәсәу̇ез ку̇рмәкгә ауар иду̇к [Ф. 228.9] һ.б.

II зат берлек сан: сән бойурсаң, бән аны қылсам имди [Ф. 112.16]; йа Йусеф, имди варсаң, Нил ирмағы ошбудыр, бақыб ку̇рсәң, мәслихәт уйләдер суға керсәң, буйыңдан тоз тофрақ кәтсу̇н имди [Ф. 116.25–28] һ.б.

III зат берлек сан: һәр кем бәһа йэтку̇рсә, алсун имди [Ф. 122.44]; ку̇реклу̇ йу̇зләр кәфен сарыб гу̇ргә керсә,у̇ку̇ш дәгу̇л, гу̇р эчендә у̇ч ку̇н дорса, қанқый дуст гу̇р эчендә, аны ку̇рсә ку̇рмәс у̇чу̇н йу̇з ду̇ндереб қачар имди [Ф. 162.40-43]; Йусефен этени йисә, қанын эчсә, Йусефемдән бәни мәхру̇м мәхзун қуйса, ку̇ңләкени һич йыртмаса, бу̇ту̇н қойса, бу арада бир хикмәт вар [Ф. 5.8]

III зат ку̇плек сан: сурарларса, ким иду̇кен айма имди [Ф. 224.20].

Эпитафик язмада шарт фигыль формасын очратабыз: kem körsä, oχïr Fatïjha süräsen [42] [Хакимзянов, 1987, с. 60].

Аналитик формалар *ирсә* яки *исә* ярдәмче фигыле ярдәмендә ясалган: *-р ирсә, -маз ирсә, -йур ирсә, -ды ирсә, -мыш ирсә.*

*-ды ирсә, -мыш ирсә* формалары у̇ткәнгә караган шарт мәгънәсен белдерәләр һәм хәзерге татар телендәге *-ган булса* тасвирлама формасына охшаш мәгънәдә кулланылалар: мундағ ду̇ш ку̇рдең исә (كورديڭ ايسا), ду̇шең ичрә ул мәқамә ирдең исә (ايرديڭ ايسا), Ғад қойусы тигрәсендә йу̇рдең исә (يورديڭ يسا) [С.Б. 11а–173]; Җәбраил Йусефә кәлди ирсә, ул Җәбраил ирдекени белди ирсә,хақ сәләми дөруди кәлди ирсә, мәхзун ку̇ңели шадеман улур имди [Ф. 76.13–16]; әгәр уйлә улур исә, Йусефи қорд йэйу̇б һәлақ қылды исә,әғзасендән бирәр нәснә қалды исә ул әғз аны бәңа алуб кәлең имди [Ф. 82.28–31]; Ходавәндем, әгәр хәта қылдым ирсә, әмрең қуйыб, сәңа ғаси улдым ирсә,атам Йағқуб хезмәтендән қалдым ирсә, тәу̇бә қылдым, пошиман улдым имди [Ф. 106.9–11]; һич гөнаһ сез бу җәфайа ду̇шмеш ирсәм [Ф. 10.15]; мундағ ду̇ш ку̇рдең исә, ду̇шең ичрә ул мәқамә ирдең исә, Ғад қойусы тигрәсендә йу̇рдең исә бир шәриф қул әлеңә керәр имди [Ф. 88.21–24].

Киләчәккә юнәлгән шарт мәгънәсендә *-р ирсә (-маз ирсә), -йур ирсә, -р исә* формалары кулланыла: әгәр санәм дүнеб, сәңа сүзләр исә (سوزلارايسا), сәңа бақыб, қаршу җәуаб әйләр исә (ايلارايسا) дәйүр ирсә (دايور ايرسا) [С.Б. 22а–294]; Әгәр сездән дуғрылық улур ирсә (ولورايرسا); әгәр өйлә улур исә (ولورايسا) [С.Б. 8б.150]; Йусефи қорд йэйүб һәлақ қылды исә (قيلدي ايسا), әғзәсендән бирәр нәснә қалды исә (قالدي ايسا) [С.Б. 8б.150] һ.б.

Шарт фигыль күпчелек язма истәлекләр телендәге һәм хәзерге татар телендәге кебек *-са/-сә* кушымчасы белән ясалган.

### 1.6.2. Затланышсыз фигыль формалары

*Сыйфат фигыльләр.* Әсәрләр телендә сыйфат фигыльнең *-ан/-ән, -мыш/-меш, -дық/-дек, -ар/-әр, -ур/ -үр, -ғучы* формалары кулланылган.

Үткән заман сыйфат фигыльләр.

*-мыш/-меш* аффиксы белән ясалган үткән заман сыйфат фигыль асылда билге мәгънәсен белдереп, атрибутив позициядә, шулай ук исемләшкән хәлдә кулланыла. Аергыч функциясендә килгәндә, сыйфатланмышы белән объект мөнәсәбәтендә тора: тәңре бәңа тәқдир итмеш (ايتمش) халән белдем [С.Б. 7а.88]; лөәлөә мәрҗәндин дүзелмеш (دوزلمش) дырнақларың [С.Б. 39а.519]; дүкәнмеш мал хәзинә нәчә дулды [Ф. 146.19].

*-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльнең исемләшү очраклары сирәк күзәтелә: ачлар туйар, сусамышлар қанур имди [Ф. 200:44].

*-ан/-ән, -ун* аффикслы сыйфат фигыль. Бу форма угыз телләре өчен хас, кыпчак, карлук-уйгур төркеменә кергән телләрдә бу формалы фигыльләр кулланылышка ия түгел. Бер төркем галимнәр *-ан* күрсәткечен *-ган* формасы кыскарып ясалган дип баралар. А.М. Щербак *-ан* формасының барлыкка килүен *-йан* күрсәткеченең фонетик үзгәрүеннән дип аңлата [Щербак, 1977, с.16].

«Кыссаи Йосыф»: күрән (كوران) кеши бихуд улуб дүшәр имди [С.Б.26а345]; буны күрән адәмиләриң ғақле шашар [Ф. 176.15]; тулун ай дик балқар иди аның йүзи [Ф. 136.9; 128.3]; тулун ай тик нурлы йүзи дуға кәлди [Ф. 92.22]; тулун ай тик йүземни сулдырыныз [Ф. 66.18] һ.б.

*-ан/-ән* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыль еш кына сыйфатланмышыннан башка кулланыла, контекстта исемләшә. Бу очракта исемнәр кебек килеш, сан кушымчалары алып төрләнә: баш килештә: бақан һәргиз җәмаленә дуймаз имди [Ф. 108.40; 122.16]; күрән хәйран сәргәрдан улур имди [Ф. 122.20]; рисаләтен күрән (كورًا) иман кәтүрер

имди [С.Б. 26а]; «Ана вә угыл»дастанында: укуғ аны дыңлай аны йаз аны рәхмәт илә йарлыкағыл [Н. 65.242]; төшем килешендә: дәргәһенә кэләнләри кирү қоймаз[Ф. 160.27]; Йусефи сатанлары, байық белгел, барчасы Йусефә улдылар қул[Ф. .204.14–15].

Чагыштырмача сирәк (21 мәртәбә) кыпчак телләренә хас *-кән, -қан, -ған, -гән* формасы теркәлгән: Йусеф әйдүр кәчкән (کچکان) үз кирү кәлмәз, хақ тәқдире буйлә иркән (ایركن), кимсә билмәз [С.Б. 18б, Ф. 102.1,2]: самәд көрәр, күргәнин һич йаңылмаз,самәд бушуб йаздығын қул аңламаз [Ф. 540].

Икән ярдәмче фигыле төп фигыль белән кулланылып, шарт мәгънәсен белдерәләр (14 мәртәбә теркәлгән): ағлар икән қәрдәшләрин үпәр қучар [Ф. 100.34; 102.12; 98.19]; шөйлә икән бутә табу қылур ирмеш [Ф. 128.10; 158.27] һ.б.

Текстта сыйфатланмышыннан башка кулланылып, исемләшү очраклары теркәлгән. Йусеф әйдүр йаратқаным халиқ дорыр [Ф. 110.9]; мунлар көрди ул шаһның ихсанени,ағырлаб, хөрмәт қылыб сәүгәнени, һәр биринә бир үтмәк вирдүгени [226.5-7]; самәд күрәр күргәнин һич йаңылмаз [Ф. 168.1].

«Ана вә угыл»дастаны текстында *-гән* кушымчалы сыйфат фигыльләр теркәлгән: харам улсун имезгән (ایمزغن) сүтим сәңа [Н. 60:97].

Бу чор әдәби истәлекләр телендә *-дық/-дек* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльнең исем фигыль функциясендә генә кулланылуын билгеләргә кирәк. Процесс исемен атап, *-дык* формасы исемнәр кебек килеш, тартым, сан белән төрләнә. «Кыссаи Йосыф»поэмасында *-дык* кушымчалы фигыль I һәм III тартым кушымчалары белән кулл анылa: I зат тартым берлектә: истәдегем улуларым бән күлдегүм эүдә икән мән бир сақынч қыйас қылдым [Ф. 66.41–42]; кем идегүм сәңа иғләм әйләйәлүм [Ф. 142.18,21]; истәдегем Мисыр ийәси дәйүр имди [Ф. 132.8] һ.б.

I тартым зат тартым күплектә: атамыздан Йусефи без алдуғымыз (الدوغم), атамыза ғаси җафи улдуғымыз,һәр нә иш кем Йусефә без қылдығымыз (قيلديغمز) [Ф. 240: 25–27] һ.б.

II зат тартым берлектә: бәллү улды сән идекең сөчи қылан [Ф. 172.30];

III тартым зат тартым берлектә: қәрдәшләри қәсд қылдығын бәйан билди [Ф. 62.46];

III тартым зат тартым күплектә: қулумыз диб, йалан сату қылдықларын, йәнә сатуб, аз бәһа алдуқларын,үч ғәйбе вар дидекләрин йазмыш имди [Ф. 240.13–16] һ.б.

*-дық* кушымчалы фигыль исем фигыль мәгънәсендә күбрәк төшем, чыгыш, урын-вакыт килешләрендә килә: дүшендә күрдегин эстәр имди [Ф. 90.8]; Йусеф нәби тәмам ғөсел қылдығында,арығ йуынуб, судан тышра кэлдегендә, хөллә кийүб, күңле шадекәм улдығында [Ф. 118.13–16]; жәмален бирин бирин әйтүр ирди үкдегенчә үкдеги артур имди [Ф. 160.3–4];

*-гән, -дүк* формаларының, ягъни традицион һәм региональ тел күрсәткечләренең бер җөмлә эчендә вариатив кулланылышы күзәтелә: Мунлар күрди ул шаһнең ихсанени,ағырлаб, хөрмәт қылыб сәүгәнени,һәр биринә бир үтмәк вирдүгени [Ф. 226:5–7].

*-ыр (-ер/-ар/-әр)* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыль. Хәзерге барлык төрки телләрдә диярлек кулланылышта булган *-ыр/-ер, -р* кушымчалы сыйфат фигыль килеп чыгышы буенча иң борынгы формалардан санала, борынгы Орхон-Енисей язмаларында ук урын алган. Тикшеренүчеләр шулай ук әлеге сыйфат фигыльнең соңрак чорларга, ягъни XI–XIV йөзләргә караган язма истәлекләрдә дә актив кулланылышын билгелиләр [Гайнуллина, 2015, с. 82–93].

Идел буе болгар әдәби теленә мөнәсәбәттә исә *-ыр/-ер* формасы сыйфат фигыль мәгънәсендә очрый. *-ар/-әр, -ур/-үр* кушымчасы сыйфат фигыль атрибутив позициядә хәзерге-киләчәк заман төсмере белән кулланыла: бән сатылур (ستلور) қол улсам, диденмиде, бәнем бәһам кем йәткүрер диден имди [С.Б. 92–187]; ғәмзә қылса дилдин кәчәр көзләрен вар [Ф. 162.8] һ.б.

*-ар/-әр, -ур/-үр* аффиксы сыйфат фигыльнең юклыгы *-маз/-мәз* кушымчалары белән ясала: Йусефи суа йәтмәздән тутар имди [Ф. 46.8].

«Ана вә угыл»дастанында: әмер қылды күкдәге учар (اوچار) куша [Н. 64.215]; *-ғучы* кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыль очрады. ороб анаң күзүни чықарғучы (چ يقاروچى) [Н. 60.47], күрек виргүче хәкыйкәт бәнвен имди [Ф. 116.12].

Әсәр телендә борынгы әдәби традициянең саклануын борынгы төрки телгә хас *-ғучы* кушымчасы да раслый, чөнки XIV гасыр истәлекләре телендә әлеге кушымча сирәк сакланган.

*-асы/-әсе (-ыйсы/-исе)* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыль.

*-асы/-әсе* кушымчалы сыйфат фигыльнең кыпчак һәм угыз төркеме телләрендә аеруча актив кулланылышы билгеләнә. *-асы/-әсе* формасы «Ана вә угыл» дастанында сыйфат фигыль буларак характерлана, һәм ул фунциональ яктан күп төрле мәгънәләрдә килә:

*-асы* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыль предметны киләчәктә булачак, булырга тиешле эш-хәл буенча характерлый: үтмәк алғыл анда

баруб йийәсән бу дөшеңни остазыңа дийәсән [Н. 60.57–58]; эстийәсен уғлыны табмайасән Хақ белүр кем қайғулары йийәсен [Н. 61.120–121];

*-асы/-әсе* кушымчалы сыйфат фигыльнең исемләшеп килү очраклары теркәлгән: нә ул йийәсен (ييياسن), ни кийәсен (كياسن) белер иде [8Б.12]; Хак дидарын көрмәйәсен ни чара [Н. 60.50] һ.б.

«Кыссаи Йосыф» поэмасында сирәк очрый: гакибәт нә буласын билү виргил [Ф. 52.10].

Истәлекләр телендә барыннан да ешрак *-мыш/-миш, -муш/-мүш, -дық/-дек, -ан/-ән* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләр һәм *-р, -ур/-үр, -ғучы* формалы традицион формалар теркәлгән. Бу чор әдәби телендә шулай ук хәзерге телгә хас *-асы, -ган* кушымчалы фигыльләр дә кулланылышта булган, истәлекләр телендә чагыштырмача сирәгрәк теркәлгәннәр.

*Хәл фигыльләр.* Хәл фигыль – фигыль һәм рәвеш билгеләренә ия булган затланышсыз фигыль формасы. «Ана вә угыл» дастаны һәм «Кыссаи Йосыф» поэмасы телендә теркәлгән хәл фигыльләр: *-ур, -а/-ә, -ү, -ып/-еп, (-уб/-үб), -убән, -у/-ү, -йу/-йү.* Сирәгрәк *-ун/-үн* (сатун алды), *-анчә, -әнчә (-кәләнчә), -а/-ә* (дота кил) формалары да кулланыла.

*-ып/-еп, -п* кушымчалы хәл фигыль борынгы төрки нигез телгә үк нисбәтләнә. Галимнәр шулай ук бу формаларның хәл фигыль мәгънәсендә инде борынгы рун язмаларында һәм борынгы уйгыр язма истәлекләрендә теркәлгән булуын һәм хәзерге көндә дә чуаш һәм якут телләреннән кала, барлык төрки телләрдә актив кулланылышын билгелиләр [Серебренников, 1979, с. 228; СИГТЯ, 1988, с. 472–473].

*-ып/-еп, -п, -уб/-үб* кушымчалы хәл фигыль күбрәк үзе ачыклаган төп фигыль белән а) бер үк вакытта булган, яки төп фигыльдән, ә) алда булган эш-хәлләрне белдерә. Мисаллар: аны күреб, нәүхәләри битәр улды, җөмләләри тунын йыртып, сачын йулды [Ф. 82.5–6]; уҗмах виреб, тәмуғ утын сатун алмаң [Ф. 68.43]; аны сатыб (ساتب), үкүш ниғмәт булдачы сән [У.И. 22]; варыб (واريب) (ул) қәрдәшләринә әйтүр имди [С.Б. 3б]; варуб (واروب) нилең ирмагинә йақын кәлди [Ф. 116.30] һ.б.

*-убан/-үбән* формалы хәл фигыльләр борынгы рун язмаларында һәм борынгы уйгыр язма истәлекләрендә теркәлгән. *-убан/-үбән* кушымчалы хәл фигыльләр «Кыссаи Йосыф» поэмасында күбрәк төп фигыльдән алда булган эшне белдерү өчен кулланылалар: көрүшүбән шөкер сәна әйтүр имди [Ф. 76.36]; йите әндам бәндләри үзүлүбән [Ф. 164.6]; қамулары дирнешүбән сурар имди [Ф. 138.28] һ.б.

*-у/-ү* формалы хәл фигыльләр: Динә дагы аглайу дүнәр имди [Ф. 62.30]; Динә мискин ағлайу йүгерер имди [Ф. 62.14]; дүшүм эчрә ағлайу үрә дордым [Ф. 62.32]; йарлы Йағқуб ағлайу анда бакар [Ф. 80.15]; йарлы Йусеф аглайу ардым дәйүр [Ф. 64.9]; Йусеф аңа аглайу җәуаб вирди [Ф. 98.4]; һ.б.

*-у/-ү, -йу/-йү, -а/-ә* кушымчалы хәл фигыльләр төп фигыль белән бер үк вакытта булган эш-хәлләрне белдерә. «Кыссаи Йосыф»: Динә дағы ағлайу (اغلايو) дүнәр имди [У.И. 10]; Йарлы Йусеф ағлайу (اغلايو) ардым дәйүр [У.И. 11]; ғәҗәбләйү дөндерер имди [Ф. 216:8] һ.б.

*-а/-ә* формалы хәл фигыльләр: соңра дура аның суы үстүн кәлмиш [Ф. 72.5]; дура дура безим илә һәмраһ улды [Ф. 94.38]; дура дура бу уғланчық йауыз улды [Ф. 94.39]; малик Дәгир дүнә дүнә ағлар имди [Ф. 100.36] һ.б.

*-а/-ә* кушымчалы хәл фигыльнең кабатланмыйча килү очрагы сирәк кулланылган, күпчелек парлы килә.

*-ун/-үн* формасы сирәк кулланыла һәм ул эшнең рәвешен белдереп килә («Кыссаи Йосыфтан): ул қулы учуз сатун (ساتون); алдачи сән [С.Б. 11б]; уғланны ким сатун (ساتون) алур [С.Б. 30б].

«Ана вә угыл» дастанында әлеге форманың әсәр телендә борынгы төрки теленә хас кабатланмыйча килү очрагы күзәтелде: *-а/-ә, -ү* кушымчалы хәл фигыль: ана тийү (تيو) түрлүк ғиззәт итәр иде [9А.22]; ғизәрәсен қәйрә (قايرى) قايرا дүнә киләндин [10А.46].

*-ғалы* кушымчалы хәл фигыль: укларымыз алғалы вардық иди [Ф. 82.23]; Йусефи қорд йийәли һич күлмәз идең [Ф. 236.30] һ.б.

*-қач, -гәч* кушымчалы хәл фигыль: қашдин ашқач итеб йэрә дүшердиләр [Ф. 62.39]; аны күргәч бикәрар бихуд ула [Ф. 156.17] һ.б.

*-әнчә* кушымчалы хәл фигыль: Йусеф анда кәләнчә күтгил имди[Ф. 72.23] һ.б.

Болгар чоры әдәби истәлекләр телендә теркәлгән хәл фигыльләрнең *-а/-ә, -ү, -ып/-еп, -уб/-үб, -убән, -у/-ү, -йу/-йү, сирәгрәк -ун/-үн, -галы/-гәле, -гыча, -гынча, -гач* формалары да килә. Бу чорда *-ып/-еп, -у/-ү, -йу/-йү, -а/-ә, -убән* кушымчалы хәл фигыльләр иң актив кулланылган форма булып тора. Яңа формалардан *-гач* вариантлы хәл фигыльнең әдәби әсәрләр теленә үтеп керешен күзәтәбез. *-а/-ә* кушымчалы хәл фигыльнең кулланылышында кайбер үзенчәлекләрне билгели алабыз, борынгы төрки әдәби телгә хас нормалар саклану белән бергә, аларның хәзерге татар әдәби теленә хас парлы кулланылышы да теркәлгән.

*Исем фигыльләр.* Бер үк вакытта фигыльгә һәм исемгә хас грамматик үзенчәлекләрне чагылдырган, традицион әдәби телдән килә торган *-мақ/-мәк* кушымчалы исем фигыль Идел буе язма истәлекләр телендә актив кулланылышка ия: андандыр җөмләси ошбу ихсан, йуқлары вар қылмақ (قلماق) аңа кәңес имди [С.Б. 33б–452]; Исраилдән хәсрәтилә айрылмақы [Ф. 94.27] сурар исә җәуаб вирмәк кәрәк имди [Ф. 66.20]; фәрманенә риза вирмәк кәрәк имди [Ф. 102.4]; Йусефи күрмәкгә ул хәйлә кылды [Ф. 124.7]; күрмәкгә йаулақ мөштақ улың имди [Ф. 120.24]; ул угланны күрмәкгә һәүәс қылын [Ф. 120.18];

*Инфинитив.* Истәлекләрдә инфинитивның *-мағa/-мәгә* формасы кулланылышка ия: җөмләләри вармаға дирнещделәр [Ф. 120.26]; ата кәулен бузмаға рәуа күрмәз [Ф. 54.38]; усанмадан дыңламаға нә рәхәтлү [Ф. 160.38] һ.б.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, традицион әдәби телләрдән килә торган *-мақ/-мәк, -мағa/-мәгә* формалары актив кулланылышка ия. Язма истәлекләр телендә фигыльләр кулланылышының нигезендә традицион әдәби телгә хас нормалар сакланышы ачык чагыла.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Идел Болгарстаны чорында иҗат ителгән әсәрләрнең грамматик төзелешен, сүз төркемнәренең кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү шулай ук (графо-фонетикадагы нормаларның чагылышы кебек) бу язма истәлекләрнең нигезендә күп гасырлык борынгы төрки, карахани-уйгыр әдәби телләргә хас традицион уртаклыклар ятуны раслый. Бу шул чор шагыйрьләренең гомумтөрки әдәби традицияләрдән иркен файдалануын, бердәм әдәби нормаларны дәвам итү омтылышы барлыгын күрсәтеп тора.

Язма истәлекләр телендә традицион грамматик формалар арасында борынгы төрки телгә хас түбәндәге үзенчәлекләр сакланган.

Идел буе Болгар чоры әдәби телендә исем сүз төркеменең сан, тартым белән төрләнеше борынгы төрки нигез телдәгечә үзгәрешсез саклана. Тартым кушымчалары рәт гармониясенә бәйле рәвештә һәм төрләнә торган нигезнең сузыкка яки тартыкка бетүенә карап вариантлашалар (*-ум/-үм, -ым/-им, -ымыз/-имиз, -умуз/-үмүз* һ.б.). Исемнең җөмләдә хәбәр булып килүе язма истәлекләр телендә шактый киң чагылыш тапкан, традицион әдәби телгә хас төрләнеш парадигмасы теркәлгән, угыз телләре өчен хас *-уз/-үз* хәбәрлек кушымчасы сирәк очрый.Килешләр системасының нигезендә төньяк төрләнешкә хас кыпчак формалары ята, шул ук вакытта угыз теленә хас кушымчаларның еш кулланылуын билгеләп үтмичә мөмкин түгел. Мәсәлән, «Кыссаи Йосыф» истәлегендә

*-ның* варианты 75 мәртәбә, *-ны/-ни* 79 мәртәбә кабатлана, угыз телләре өчен хас *-ың* формасы 42 сүздә теркәлгән, *-ы/-и* 64 мәртәбә кабатлана. «Ана вә угыл»дастанында шулай ук кыпчак төрләнеше күпчелекне тәшкил итә (13 очрак), *-ы/-и* очрагына 5 сүзформа теркәлгән. Борынгы төрки нигез телдәге охшату-чагыштыру, корал килеше әдәби тел традициясе буларак сакланган, чагыштырмача сирәк очрый. Идел Болгарстаны чорында иҗат ителгән әсәрләрнең телендә алмашлыкларны куллануда борынгы төрки, карахани-уйгыр әдәби телләренә хас үзенчәлекләр ачык аерымлана – *қанда*, *қанча қанқи*, *қамуғ*, *нәшә*, *нәтәк*, *нәлүк*, *шол*, *ошбу*, *шөйлә*, *ушал* һ.б. Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» әсәрендә сан сүз төркеменә кергән 200 дән артык берәмлек теркәлгән, җыю санының *-ыла/-илә, -ула/-үлә* формасы актив кулланылышка ия булуы билгеләнә. Истәлекләрдә әдәби тел традициясе һәм сөйләм теле җирлегендә формалашкан бай һәм сурәтләүләүдә камил бөтенлек тудыруга ярдәм иткән сыйфат сүз төркеме чагылыш тапкан. Әсәрләрдә зур күпчелекне борынгы төрки чыгышлы сыйфатлар тәшкил итә, гарәп-фарсы теленнән кергән алынма сыйфатларның күп булуын да билгеләргә кирәк. Поэмада язма һәм сөйләм теленең бай мөмкинлекләре файдаланылган, охшату-чагыштыруга корылган сыйфатларга зур урын бирелгән. Истәлекләрдә теркәлгән фигыльләр кулланылышының шактый үзенчәлекле картинасы ачыклана. Күренгәнчә, бу чорда әле борынгы төрки әдәби традиция шактый тотрыклы саклана: *-ды/-ди, -мыш/-миш, -муш/-мүш, -дық/-дек, -ур/-үр, -ғучы, ысар/-исәр, -дачи, -ғыл/-гил, -ың/-иң, -әлүм/-алум* һ.б. Әдәби текстлар теленә үтеп кергән угыз тел үзенчәлекләре чагылыш таба: *-йур, -а, -ан/-ән* һ.б. Бу чор әдәби телендә шулай ук хәзерге телгә хас *-асы, -ган* кушымчалы фигыльләр дә кулланылышта булган, истәлекләр телендә чагыштырмача сирәгрәк теркәлгәннәр. Болгар чоры әдәби истәлекләр телендә теркәлгән хәл фигыльләрнең *-а/-ә, -у, -ып/-еп, -уб/-үб, -убән, -у/-ү, -йу/-йү,* сирәгрәк *-ун/-үн, -галы/-гәле, -гыча, -гынча, -гач* формалары да килә. Бу чорда *-ып/-еп, -у/-ү -йу/-йү, -а/-ә, -убән* кушымчалы хәл фигыльләр иң актив кулланылган форма булып тора. Яңа формалардан *-гач* вариантлы хәл фигыльнең әдәби әсәрләр теленә үтеп керешен күзәтәбез. *-а/-ә* кушымчалы хәл фигыльнең кулланылышында кайбер үзенчәлекләрне билгели алабыз, борынгы төрки әдәби телгә хас нормалар саклану белән бергә, хәзерге татар әдәби теленә хас парлы кулланылышы теркәлгән. Шул рәвешчә, Болгар чорында Идел буе төрки әдәби теленең үз нормалары тотрыклана һәм ныгый барган. Бу күренеш тикшерелгән әдәби әсәрләр, эпитафик язмалар теле мисалында раслана.

## 2. АЛТЫН УРДА ЧОРЫ ИДЕЛ БУЕ ТӨРКИ-ТАТАР ЯЗМА ӘДӘБИ ТЕЛЕНЕҢ МОРФОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Алтын Урда чоры төрки-татар язма әдәби телен турыдан-туры татар язма әдәби теленең элгәресе, аның чишмә башы дип саный алабыз. Шул ук вакытта әлеге язма әдәби мирас гомумән төрки халыклар мәдәнияте үсешенең дә әһәмиятле этабын тәшкил иткәнлеген дә билгеләп үтәргә кирәк. Бу турыда Әмир Нәҗип болай ди: «Күп кенә төрки халыкларның (мәсәлән үзбәк, татар, казак, төрекмән һ.б.) әдәбияты һәм әдәби тел тарихы Алтын Урда әдәби теле, шул чорда иҗат ителгән әдәби мирас белән тыгыз бәйләнгән» [Наджип, 1961, с. 20]. Күренекле тюрколог, урта гасыр төрки язма истәлекләребезне өйрәнүгә зур өлеш керткән Әмир Нәҗипнең гомумтөрки әдәби телләр тарихының үсеш этаплары хакындагы хезмәтләрендә татар әдәби теленең характерын билгеләгән төп моментлар чагылыш тапкан [Наджип, 1975, с. 16]. Галим Идел буенда төрки язма әдәби телнең XII–XIII йөзләргә нисбәтләнүен, ягъни әле монгол яулап алуларына кадәр үк Түбән Идел регионында үзенчәлекле классик төрки-татар язма әдәби теленең гамәлдә йөрүен күрсәтә, әлеге язма әдәби телнең диалекталь нигезе, Урта Азия әдәби теленнән аермалы буларак, катнаш кыпчак-угыз (угыз-кыпчак) теле булуын дәлилли. Тел тарихы фәнендә билгеле булганча, милләткәчә чордагы гомуми әдәби телләрнең, төрле тарихи-иҗтимагый шартларга бәйле рәвештә, бер географик төбәктән икенче төбәккә күчеше белән очрашабыз. Әлеге күчешнең асылы борынгы традицион тел үзенчәлекләрен күпмедер дәрәҗәдә саклаган хәлдә, әдәби телнең диалекталь нигезе үзгәрү юлы белән бара.

Җучи Олысы бөтен Евразиядә урта гасырларның иң зур дәүләте, элеккеге күчмә һәм яңа шәһәр культурасының классик симбиоз

кушылмасын тәшкил иткән цивилизация үзәге булган. Аның составына төркиләр яшәгән Идел, Урал буйлары, Урта Азия, Казакстан, Себер, Кырым, Дәште Кыпчак җирләре кергән, элек аерым дәүләтләргә караган төрки халыклар бер дәүләт эченә берләшкәннәр. Бер дәүләт эченә керү элек шактый аерылып торган төрки халыкларның һәм, беренче чиратта, аларның телләренең охшашлануына китерә [Фахрутдинов, 1995, с. 108–110; История татар, Т. 3, с. 310–365]. Бәркә хан (1209–1266) идарә иткән чорда ислам дине Җучи Олысының рәсми дине итеп игълан ителә. Җучи Олысында диннәрнең, аерым алганда, ислам диненең таралышы М.Г. Госманов, Н.М. Малов хезмәтләрендә шактый тирән яктыртылган [Усманов, 1985, с. 180; История татар,Т. 3, с. 552–682]. Урта гасыр әдәбияты белгече Х. Миңнегуловның билгеләвенчә, Җучи Олысында язма мәдәниятнең тууы һәм үсүе өчен тиешле җирлек, уңайлы шартлар булган, һәм, чыннан да, бу дәвер әдәбияты шактый тәрәккыяткә ирешкән дә. Кызганыч ки, төрле сәбәпләр аркасында Алтын Урданың шәһәрләре генә түгел, күпчелек язма истәлекләре дә юкка чыккан. Исәннәренең дә тик бер өлеше генә ватаннарында сакланып калган [Миңнегулов, 1999, б. 25–52]. Безнең көнгә килеп җиткәннәре төрле характерда булып: ярлыклар, каберташ язмалары, гыйльми хезмәтләр, сәяхәтнамәләр, сүзлекләр, Җучи Олысында язма әдәбиятның зур үсешкә ия булуын дәлиллиләр. Шулай да язма истәлекләр арасында төп урынны матур әдәбият әсәрләре алып тора. Алар арасында Борһанетдин углы Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» (1310) – кыскартылма КР., Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» (1358) – кыскартылма НФ., Харәзминең «Мәхәббәтнамә» (1353) – кыскартылма Мн., Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (1342) – кыскартылма ХШ., Х. Кәтибнең «Җөмҗөмә солтан» (1369) – кыскартылма Җҗ., С. Сараиның «Гөлестан бит-төрки» (1391) – кыскартылма Гб. һәм авторы билгесез «Кисекбаш» (XIV) – кыскартылма – Кб. әсәрләре бар. Казан мирасханәләрендә кулъязма китап коллекцияләреннән урта гасырда Идел буе, Алтын Урда мәдәни үзәкләрендә күчерелгән нөсхәләр очрамый, әмма тарихчы галим Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, С. Вахидиләрнең XIV–XVI гасыр документлары белән эш итүләре мәгълүм. Башка илләрдә, мәсәлән, Төркиядә, Европа китапханәләрендә урта гасырда күчерелгән кулъязмалар фәндә билгеле.

Алтын Урда чоры әдәби теленең характерын билгеләүдә тюркологиядә бердәм караш юк. Шактый киң таралган карашлардан – XIV йөзнең урталарына Алтын Урданың мәркәзе булган Идел буенда

караханидлар дәверендәге уйгур әдәби традициясенең көчле йогынтысында булган, шул ук вакытта кыпчак элементларын күбрәк, угызныкын азрак алган үзенә бер аерым әдәби тел формалаша [Нәҗип, 1957, б. 95]. Танылган галим, татар әдәби тел нормаларының үсеш юлларын тарихи эзлеклелектә өйрәнгән В.Х. Хаков Идел буе Болгар дәүләтенең Алтын Урда составында автономия рәвешендә яшәвен билгели. Күп шәһәрләр, шулай ук мәдәният һәм мәгърифәт үзәкләре җимерелүгә карамастан, җирле сөйләм һәм язма традицияләр сакланып кала. Яңа шартларда болгар, кыпчак телләренә нигезләнгән, угыз тел үзенчәлекләрен үзенә берләштергән Идел буе төрки әдәби теле үсеп чыга. Бу – безнең борынгы бабаларыбызның язма китап теле, яки, башкачарак әйткәндә, билгеле күләмдә халыкның җанлы сөйләм тел үзенчәлекләрен эченә алган элгәреге (иске) татар әдәби теле [Хаков, 2003, б. 54].

Алтын Урда чоры язма истәлекләрнең сүз төркемнәрен, алардагы грамматик формаларның кулланылыш үзенчәлеген өйрәнү шул чор әдәби телнең нигезен билгеләү өчен әһәмиятле. Әдәби истәлекләрдә теркәлгән традицион уртаклыклар саклану белән беррәттән, әлеге дәвердә әдәби телнең үзгәреше белән очрашабыз. Борынгы төрки, караханлы-уйгыр әдәби тел өчен хас традицион формалар белән бергә шул чор гомумхалык сөйләм теле өчен хас күрсәткечләр теркәлгән. Тикшерүдә статистик алым куллану сүз төркемнәренең парадигмасын, грамматик категорияләрнең кулланылышын җентекле күзәтергә, әсәр текстында грамматик формаларга хас нормаларны билгеләргә, норма вариантлылыгын ачыкларга, бу ядкәрләрдә чагылган әдәби телнең диалекталь нигезен билгеләргә мөмкинлек бирә.

## 2.1. Исем

Алтын Урда чорында язылган текстларда исем сүз төркеменә хас сан, тартым, хәбәрлек, килеш грамматик категорияләренең кулланылышын өйрәнү әдәби телнең торышын ачыклау өчен әһәмиятле.

**Сан категориясе.** Алтын Урда чоры язма истәлекләрендә исем сүз төркеменә хас сан грамматик категориясенең кулланылышы традицион әдәби тел нормаларына якын.

Берлек сан сүзнең нигезе белән тәңгәл килә, кушымчасыз белдерелә, предметның берлеген күрсәтә. *-лар/-ләр* кушымчасының төп грамматик мәгънәсе предмет һәм күренешләрнең бердән артык булуын, билгесез күплеген белдерә. Алтын Урда чоры язма истәлек-

ләрендә кулланылган сан категориясенең белдерелеше формаль күрсәткечләре буенча һәм функциональ яктан нигездә охшаш.

Берлек сандагы исем предметларның реаль берлеген белдерә: сен бу оғланны сениң қапуғыңда қойғыл [КР. 10.7], инкән бүтәси бирлән қобды [КР. 13.10], йағыз йирни сув үзә ким сақлайур [КР. 46.1]; йә Йусуф нә күрүклүг йүзүң бар көрклүг көзүң бар... көрклүг сачың бар [НФ. 360-14, 16, 17]; қоруғ адәм башы [Җж. 159], йарлыны вә байны [Җж. 39], Ғали өбәр ол кесүк баш йүзини [Кб. 139.4]; ақлы келди кәндүнә ачды көзин [Кб. 139-31]; көләр ай хөснингә [Мн. 228]; йир өптим [Мн. 38]; һавадан инди аңсызда бу лачун [ХШ. 39v.14]; ошбу тағ етәгиндә онгур бар [ХШ. 14v.15]; нә иңиндә тун бар нә башында сач [Җж. 57.16]; йүзиндин нур ақар [Җж. 137.22] һ.б.

Хосусый затларны белдергән исемнәр өйрәнелә торган текстларда берлек санда теркәлгән: Ғабдулла атынға чықты [КР. 97.20], Нуд қауми иман келтүрмәди [А12.14], Ғомәр оғлы Габдуллаһ риуайат қылыр [НФ. 1.4]; беш намаз қылур Ғали ақты билә [Кб. 139.2]; бу йулға төшсә, Әфлатүн телүргәй [Мн. 281]; синин хүснүнгә Хорәзми ғашиқ [Мн289], атым ирди Җөмҗөмә [Җж. 44.19] һ.б.

Сан белән ачыкланган исемнәр күпчелек мисалларда берлек сан формасында килә: توقوز اوغلان توغدى – тоқуз оғлан тоғды [КР. 14.7]; اوج يوز ييل – үч йүз йыл [КР. 11.20]; миң җаным болса фида қылдым [КР. 511.7], йетмиш йети иқлим шаһы [ХШ. 31v]; Рәсүл олтурмыш ирди төрт йар илә [Кб. 137.11]; келди беш йүз мусулман чешти илин [Кб. 142.4];отуз уч мең сахаба җумлә билә [Кб. 137.12]; миңи натманлар ирди миңи бургу [Җж. 44.7] һ.б.

Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-Фәрадис» әсәрләрендә микъдар саннары янында нумератив сүзләр кулланылганда, ачыклаган исемнәр күплек сан кушымчалары алган. Мәсәлән, баш: алты баш қул қарвашлар ким кәферләр илкиндә әрди [НФ.97.14]; Әбубәкр бу йети баш кишиләрне алып әвенгә кәлде [НФ.257-15] һ.б.

Күплек сан мәгънәсе Алтын Урда чоры әдәби әсәрләр телендә морфологик һәм синтаксик юл белән белдерелгән. Санала торган предмет һәм күренеш исемнәрендә күплек сан *-лар/-ләр* кушымчасы алып төрләнгәндә, билгесез күплекне белдерә. Мисаллар: түрлүг түрлүг тонлар кеӡүрди [КР. 7.9], Салих анасының қойларын сақлар [КР. 10.12], йулдузларны ким туғурур ким батунур [КР. 46.1], оғланлары, аталары; бу бағны бу қуллар бирлә сизгә бағышладым [НФ. 246.17]; хисабсыз көп чәрик қылды [ХШ. 222]; көңүл бахрында көп гәүһәрләриң бар

[Мн. 292а]; сахабалар кайттылар көз йәш илә [Кб. 138-37]; басар анлар йүзләринә қыздуруп [Җҗ. 55-24] һ.б.

Парлы тән әгъзаларын белдергәндә исем сүз төркеме берлектә дә, күплектә дә кулланылган: меним елким аҙақымны бәрақ бағлағыл [КР. 512.2]; барчасының ил айақы бағглыдур [Кб. 140.2]; көзүм бирлә көрдүм ол кәфирләрни [НФ. 12-13]; қазғу қоймас көзләриңни уйқуға [Кб. 138.17]; йени бирлә сөртәр йүзи көзини [Кб. 139.5]; бирсә чехраң көзләрә нур [Мн. 236]һ.б.

Исемнәрнең күплек формасы *-лар/-ләр* экспрессив максатта кулланылырга мөмкин: көңүлләре бөрү көңүлләри мәңизлик болгай [НФ. 402.6]; бу хараплуқлар җүмләсе андин турур [НФ. 82.3]; Тәңригә асхаб шүкүрләр қылдылар [Кб. 142:28]; көп сөз сөзләр ағзындин отлар сачар [Кб. 140.35]; йүзләриңә отдин ғоллар олуп [Җҗ.57.2]; көңүлләрни йарутты әдгү аты [ХШ. 4 v]; күр қылдым вәфалар [Мн. 144]; айытсун бәндә Хорәзми доғалар [Мн. 81] һ.б.

Алтын Урда чоры язма истәлекләре телендә предметларның сан буенча күләмен ачыклау күренеше теркәлгән, бер-берсенә каршы куелган берлек һәм күплек формалары белән белдерелгән. Берлек сан кушымчасыз килә, сүзнең нигезе белән туры килә, күплек сан *-лар/-ләр* кушымчалары белән ясала. Мәгънәләренә килгәндә берлек сандагы исем предметларның реаль берлеген белдерә, хосусый затларны белдергән исемнәр һәрвакыт берлек санда теркәлгән. Күплек кушымчасы *-лар/-ләр* предметларның бердән артык булуын, аның билгесез күплеген белдерә. Текстларда исемнәрнең күплек формасы, экспрессив максатларда кулланылып, мәгънә төсмерләрен көчәйтүне күрергә мөмкинлек бирә.

**Тартым категориясе.** Тартым – төрки телләр өчен хас үзенчәлекле грамматик категория, тартым кушымчалары ярдәмендә предметның кайсы затка караганлыгын белдерелә. Тартым белән төрләнеш өч затта, берлектә һәм күплек санда килә. Алтын Урда чоры истәлекләре телендә тартым категориясен өйрәнгән галимнәр Э.Н. Нәҗип, Я.С. Ахметгалеева, А.Р. Исхакова, Ф.Ш. Нуриева, Г.Ф. Гайнуллина һ.б. төрләнешнең, нигездә, борынгы төрки телдәгечә саклануын билгелиләр.

I зат тартымлы исемнәр *-ум/-үм, -ым/-им* кушымчалы берлек формасында очрый: ағзым [КР. 120r], алтунум күмүшүмни [КР. 167r-16], балам [КР. 246r], улум бағрым йүрәгим [ХШ. 65v.12], атам анам [Гб. 66.5], арсланым [Кб. 140.25], атым [Кб. 138.41], ағзым [Җҗ.52.13], көзүмниң йашы [Мн. 164б-8], сөзләримни башлағайын [Мн. 162а.2] һ.б.

Иренләшү гармониясенең саклануы буенча I зат тартым кушымчаларның язылышы традицион әдәби тел нормаларына якын, күпчелек *-ум/-үм* формасында теркәлгән.

Әсәрдә I зат тартымлы исемнәрнең күплек саны күрсәткече – борынгы төрки әдәби телдән килгән традицион *-мыз/-миз, -муз/-мүз* кушымчалары норма булып тора. I зат берлек күрсәткечләре белән чагыштырганда, әлеге формалар сирәк кулланылган: сувумыз [КР. 35v-7], бизим қулумуз [НФ. 112-7], анамыз [НФ. 173-1.6-8], башымыз үстүндә [Гб. 76.3], өмүрүмиз [ХШ. 28r-14], қанатымыз йоқ турур [Кб. 142.10], қылғыл иманымызны [Мн. 173а.8] һ.б.

II зат берлек санда *-ың/-ең, -уң/-үң* кушымчалары ялгана: ағызың [КР. 120 v], ашлықың [КР. 42 v.13], адақың [НФ. 21.5], көзүң Кәшмир ғазисыңға устад [Мн. 164б-4], хуснуңға көрклүсән [Мн. 164б.15] һ.б.

II зат күплектәге тартым кушымчасы чагыштырмача сирәк очрый, традицион әдәби телгә хас *-ыңыз/-иңиз* вариантында кулланыла: сувларыңыз [КР. 26v.2], адақларыңыз [НФ. 250.16], мәхриңизни асрар [Мн. 171а.2] һ.б.

III зат берлек санда *-ы/-и, -сы/-си,* III зат күплектә *-лары/-ләри* кушымчалары ялгана. III зат берлек санның мәгънәсе киң, ул сөйләмдә катнашмаган башка бер затка гына түгел, күп төрле әйберләргә ишарәли: көк әшики ачылды [КР. 513-15]; бәғер йәши көз йәши [НФ. 304]; нә гәүдәси нә айақы нә әли [Кб. 137.19]; гөмбәзә охшар ирди аның башы [Кб. 140.18]; көңилдә ғишқы болса [Мн. 251], халық ханы [Мн. 428]; тәңриниң арсланы [Кб. 250,214] һ.б.

III зат күплектәге тартым мәгънәсен белдергән *-лары/-ләри* кушымчалары текстта шулай ук чикле кулланылган: ағызлары [КР. 229v-14. 97r.13], бутлары [КР. 57r14], [НФ. 337-13], көңүлләри [НФ. 65.15]; җүмлә пинһан ишләри мәғлүм ола [Кб. 140-13];отдин ғоллар йүзләриңә сәзадур [Кб. 57-12]; тәнләри өз қанлариға булғанып [Җж. 40-3] һ.б.

Алтын Урда чоры әдәби истәлекләр телендә тартым грамматик мәгънәсе өч затта һәм санда белдерелгән. Тартым кушымчаларының күрсәткечләре борынгы төрки нигез телдәгечә кулланылган, рәт гармониясенә бәйле рәвештә һәм төрләнә торган нигезнең сузыкка яки тартыкка бетүенә карап вариантлашалар. Күплек сандагы тартым кушымчаларының тартымның берлек саны белән чагыштырганда сирәк теркәлүе билгеләнде. Исемнәрнең төрләнешенең парадигматикасын җентекле өйрәнү шул чор халык сөйләм теле өчен хас грамматик

формаларның текстларда очрамавын, традицион формаларның норма булып торуын күрсәтә.

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | -ум/-үм, -ым, -им | -ы)мыз, -(и)миз, -(у)муз, -(үмүз) |
| II зат | -ың/-иң, -уң/-үң | -ыңыз/-иңиз, -уңуз/-үңүз; |
| III зат | -ы/-и; -сы/-си | -лары/-ләри |

**Килеш категориясе.** Алтын Урда чорында язылган әдәби әсәрләр телендә төрле килеш формаларының кулланылышын, статистик чагыштырмасын өйрәнү XIV–XV гасыр өчен хас төрләнеш тибын, грамматик норманы ачыкларга, килешләр системасындагы үсеш-үзгәрешне билгеләргә мөмкинлек бирә.

*Баш килеш.* Алтын Урда чоры язма истәлекләре телендә баш килешнең күп төрле функцияләре теркәлгән.

Насретдин Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия» текстында: йәти қат көк әшики ачылды [А.513.15]; бир қуч алыб кәлүр [А.513.24], бир кисәк булут иди [А.515.7], мондағ болса мәнин боғузум нәтәк кисәр [А.513.5] һ.б.

«Нәһҗел-фәрадис»та: Ғомәр оғлы Габдуллаһ риуайат қылыр [1.4]; хамир майа [33], бәғер йәши көз йәши [304], хәдис мәғнәси [3.5] һ.б.

«Җөмҗөмә солтан»да: монча шаһлар кем җиһана килделәр [14.1]; бер таифә күрдем анда мән [10.19]; ишиттим дүнйаишин билүк анық [1.2] һ.б.

«Кисекбаш китабы»нда: нәғрә орды ол ғәзи [169]; йүзи ай [130]; күз йәши [24, 135], гәр шәфәқәт қылмасан [69], йити күн [99] һ.б.

«Мәхәббәтнамә»дә: көләр ай хөснингә [228], бу йулға төшсә, Әфлатүн телүргәй [281]; йир өптим [38], әй сақи [150, 380, 281], әй шаһ [38, 252] һ.б.

Иялек килеше. Иялек килеше тартымлы һәм тартымсыз төрләнештә нигездә نینک – *-ның/-ниң,* نونک – *-нуң/-нүң* килеш кушымчаларын ала.

«Кыйссасел-әнбия»дә: отнуң нурындин [А.8.1]; җиһанның ортасын Шамға бирди [А.6.15]; Салих анасының қойларын сақлар [А.10.12].

Угыз телләренә хас *-ың* варианты бары алмашлыклар төрләнешендә теркәлгән: сәниң мәниң бирлә ни ишиң бар [А.39.10] һ.б.

Иялек килеш кушымчасының язылышына бәйле истәлек орфография-се традицион әдәби телгә якын, ягъни кушымча нигезгә ялганмый: جهان نينک[А.6.15]; قوم نينک [А.8.8]; آى نينک [А.11.16]; بت نينک [А.8.9]; ايش نينک [А.172.10] һ.б.

Нигездә ирен гармониясе саклана, аерым очракларда сакланмавы теркәлгән: اوت نينک [А.432.10]; کوک نونک [А.7.23]; اولوعلار نينک [А.69.8]; قدوق نينک [А.68.21]; قوش نينک [А.438.18]; يوسف نينک [А.178.21]; اوت نونک [А.8.1] һ.б.

Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә نينک, نونک – *-ның/-нин, -нуң/-нүң* кушымчалары ялганган: Кәсриниң сарайы [НФ. 82.3]; қуйуғуң сууы [НФ. 385.78], түннүң әүүәли [НФ. 313.5] һ.б.

*-ың/-иң* кушымчалары алмашлыклар төрләнешендә күзәтелә: синиң атаң [НФ.14.12], аның түшәги [НФ. 47.15], синиң йаранлар [НФ.47.17], бизим қулумуз [НФ. 112.7] һ.б.

«Нәһҗел-фәрадис» әсәре өчен дә иялек килеше кушымчалары-ның аерым язылуы норма булып тора: حوض نينک – хаузның [НФ. 62.5] ~ حوض نونک – хаузнуң [НФ. 62.7]; هابيل نينک – Һабилның [НФ. 338.3] һ.б.

«Кисекбаш китабы»нда килеш ننک – *-ның/-нин* калын һәм нечкә вариантларда кулланылган: Ғалиниң ерлигинә [11,39], тәңриниң арсланы [250, 214], рәсүлниң йүзи [21] һ.б.

Килеш кушымчалары эзлекле рәвештә нигезгә ялганмаган, язуда ى күрсәтелмәгән: يوزننک [131]; تاشننک [210]; حق ننک [260]; ديولارننک [220] һ.б.

«Җөмҗөмә солтан» истәлегендә иялек килеше чагыштырмача аз очрый, ننک – *-ның/-нин* кушымчасы белән бирелгән,бары ике мисалда *-иң* аффиксы теркәлгән: алтынчысының аты [Җж. 20б.3] тәмуғның ату [Җж. 20а.8], ғәләмиң сәрвәри [Җж. 18б.11] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки» әсәрендә *-ның/-нин* вариантлары язылган, ғүмрүмниң раст малы [19], хатынның қызы [23В] һ.б. Килеш күрсәткечләре нигездән аерым языла: کيشى نينک[185]; عمرومنينک [235]; شيوه لار نينک [236] һ.б.

Хәрәзминең «Мәхәббәтнамә» поэмасы өчен дә *-ның/-нин* кушымчалары норма булып тора: тәнриниң атын [1], фәләкниң дәфтәрендин [3], кишиниң җәмалы [122], падишаның мәрхәбәси [143], қойашның нуры [245] һ.б.

Иренләшү гармониясе эзлекле сакланмый, чагыштыр: йүзүңнүң нуры [117], хузурнуң зәкәти [363], көзүмниң йашы [119], Нәмрудның мәғзы [12] һ.б.

«Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә иялек килешенең نینک – *-ның/-ниң* и نونک – *-ниң/-нүң* формалары теркәлгән: ол атның баһасы [959], бу қызларның бири [644], кисиниң ким көңилдә ғишқы болса [251], қулуңнуң би йазуқыны бағышла [171] h.б.

Кушымчаларда иренләшүнең тотрыклы сакланмавы теркәлгән: күкниң уғатыдин [1487]; фиғлимнүң тилекинде йоқ ол күч [108] h.б.

Иялек килешенең кулланылыш чагыштырмасын өйрәнү әсәрләр телендә кушымчаларның, нигездә, бердәм нормалар саклануын күрсәтә. «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис» текстларында иренләшү гармониясе эзлекле сакланган, «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхәббәтнамә», «Җөмҗөмә солтан» әсәрләре телендә ирен гармониясенең бозылу очраклары бар, ә «Гөлестан бит-төрки» һәм «Кисекбаш китабы» да бары نینک – *-ның/-ниң* вариантлары теркәлгән. *-ың* угыз варианты «Җөмҗөмә солтан»да бары ике мисалда очрады, алмашлык төрләнеше өчен норма булып тора.

*Юнәлеш килеше.* Насретдин Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия» текстында юнәлеш килешенең *-ға/-гә* варианты теркәлгән: дингә [А.5.5; 6.11], путға [А.6.3], сөзгә [А.6.12] h.б.

Борынгы нөсхәдә III зат тартым кушымчасы алган исемнәрдә өч төрле төрләнеш тибы очрый. 14 бит күләмендә алынган исәпләүләрдән күренгәнчә, *-ынға* формасы – 15 мәртәбә, *-ыға* – 4 мәртәбә, *-ына* 3 мәртәбә теркәлгән: қайуңыз атынға чықса [А.509.6], анамның адақынға түшүб [А.512.8], боғазынға орды [А.512.23] h.б.

Җөмләдә килеш кушымчаларының вариатив кулланылышы күзәтелә: қарға салдурды қайсының атына чықса аны қорбан қылур болды Ғабдулла атынға чықты [А.97.20] h.б.

ـعا – *-ға* аффиксы нигезгә ялганмый, аерым языла: аҙақға (اذاق عا) [А.5.6], мөсүлманлықға (مسلمان لیق عه) [А.5.11], Салихға (صالح عه) [А.6.7], самға (سام عه) [А.6.16] h.б.

غا / کا + ـنـ – *-н + ға /-н + гә*, عا + ـمـ – *-м + ға* очраклары һәрвакыт бергә язылган: قومینعـ қауымынға (ا) [А.5.2]; ایوینک – эүингә [А.16.20], اعزینعا – ағзынға [А.7.12] h.б.

«Нәһҗел-фәрадис»әсәрендә юнәлеш килешенең *-қа/-кә, -ға/-гә* кушымчалары теркәлгән: көкләргә тәқы тауларға ғарза қылды, Абубәкр оғлыны Мисрға бикликкә ыза бирди [133.6]; йә Муса қазаңны дарйаға ырғыл қачан Муса дарйаға урмыш әрди [73.8]. 1–10 битләрдән алынган исәпләүләрдән күренгәнчә, *-қа* формасы – 21 мәртәбә, *-ға* исә 8 мәртәбә кабатлана, тартымсыз төрләнештә *-а* кушымчасы күзәтелмәде.

I һәм II зат тартымлы исемнәргә юнәлеш килешенең *-ға* һәм *-а* вариантлары ялгана: анамға сихәт бирсә [221.12]; анлар тәқы сәламымға җавап қылдылар [94.3]; ул ким әрсә евемә кирди [401.5] һ.б.

III зат тартымлы исемнәрдә *-н-* элементы эзлекле саклана: *-н + -ға/-гә, -н + -а/-ә:* сол йанына бағар [53.13]; алтынға тәқы йанларынңа тәқы арқаларынға басқайлар [250.10]; кичә җарийәсинә әйди [170.12] һ.б.

Тартымсыз төрләнештә юнәлеш килеше кушымчалары – аерым, тартымлы төрләнештә исә кушылып языла: тәңриға [58.1, 2, 3], Нәҗәшиға [80.4] һ.б.

«Җөмҗөмә солтан»: юнәлеш килеше *-ға/-га, -қа/-ка* кушымчалары белән белдерелә, бары тик ике очракта гына *-а/-йа* угыз формасы кулланылган: бүзгә чолғаныпп [А.15а.13]; күзин күккә тикәп [А.16б.3], гизди шам илендин йәнә бир илә [А.15б], килдиң дүнйаға [А.15а.15] һ.б.

I зат тартым кушымчасы алган исемнәрдә юнәлеш килешенең ике төрле төрләнеш тибы очрый, исәпләүләрдән күренгәнчә, *-ым + -ға* формасы – 14 мәртәбә, *-ым + -а* 8 мәртәбә кабатланган: инҗимә [35], хүснимә [37], мәхбүбимә [6], сүзимгә [14], мойнымға [28, 29, 3], қанымызға [7] һ.б.

III зат тартымлы исемнәрдә *-н-* элементы эзлекле саклана: *-н + -ға/-гә. -н + -а/-ә, -нга* күрсәткече норма булып тора: илинә [36], тау тишигинә [32], йүзләринә [5, 15, 22], күтәрип муйунларыға алдылар [30] һ.б.

«Кисекбаш китабы»нда юнәлеш килеше *-ға/-қа/-а* кушымчалары белән белдерелә. Тартымсыз төрләнештә *-ға/-қа* һәм аның угыз варианты *-а* бертигез кулланылган, 13 мәртәбә кабатланган: туфраққа [31], күккә [54, 130], башқа [63] ~ башға [255], Дүлдүлә [107], йирә [123, 218], сарайа [151], манарайа [132] һ.б.

I зат тартымлы исемнәргә юнәлеш килешенең *-ға* һәм *-а* вариантлары ялгана: морадымға [48], мақсудыма [48], башымға [83], барчамызға [248] һ.б. III зат тартымлы исемнәрдә *-н-* элементы эзлекле саклана: йүзинә [30], дустына [196], җанына [168, 212] һ.б. Архаик *-кәр* кушымчасы тилимкәр сүзендә теркәлде.

Тартымсыз төрләнештә غا – *-гә/-ға,* كا – *-кә* аерым да, кушылып та язылган: توفراقغا – туфрақға [31], باشغا – башға [255], كوككا – күккә ( [134], Ғәлигә (على كا) [189] һ.б.

«Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә юнәлеш килеше قا – *-қа/-кә,* كا,غا – *-ға/-гә*, ـه – *-а* кушымчалары белән тәгъбир ителгән. Тартымсыз төрләнештә традицион әдәби телгә хас саңгырау قا – *-қа* күрсәткеченең яңгырау вариантына караганда 4 тапкыр артык кулланылуы, норма

булып торуы аерымлана. *-қа:* сувқа [23r], қунаққа [20r], Бануқа [20v], йазықа [21r], танқа [21v] һ.б.

*-ға:* отға [24v], бағға [12r], путға [2r], башға [15v], қылу тауларға тамаша [15v] һ.б.

*-гә, -кә:* сәкәргә [23v], елгә [25r], ишкә [21v], йирәккә [24r], әвгә [21r] һ.б.

*-а/-ә* бик сирәк ялганган: сува (سووا) [22r], ишә (ایشه) [81v] һ.б.

Кушымчалар нигезгә ялганмаган: کونکل کا – көңүлгә [1v]; اوت غا – отға [3р], تاغ قا – тағқа [64v], چیچاک کا – чичәккә [87v], الیم کا – әлимгә [21v] һ.б.

«Мәхәббәтнамә» әсәрендә *-ға/-гә, -қа/-кә, -а/-ә* юнәлеш килеше кушымчалары нигездә саңгыраулыкта-яңгыраулыкта яраша: йиргә түшүптүр [87], ғәләмгә берүр [345], қайы йиргә бойырса [11], тойға кирү [76], башдин айаққа җансын [115], қыйаматқа текин қалсын атың [436] һ.б.

Текстта юнәлеш килешенең *-ға/-қа* формасы 65 мәртәбә, ә көньяк төрләнешкә хас *-а/-ә* варианты 10 мәртәбә кабатлана: көңүлни бағлағайын өзгә йара [365], зүлфүн нәсими рума ескәй [343], әгәр султан әсан, мискинә рәхим ит [257], бирсә чехраң көзләрә нур [236], китабат башладым әнама йиткәй, мәһаббәтнамә Миср шама йиткәй [60] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки» әсәрендә *-ға/-гә, -қа/-кә* юнәлеш килеше кушымчалары нигездә саңгыраулыкта-яңгыраулыкта яраша, аерым мисалларда *-а/-ә* угыз варианты теркәлгән: кәмигә [17v], мәликкә [17v], балчыққа [27v], атаға анаға [33r] һ.б.

III зат тартымлы исемнәрдә *-н-* инфиксы эзлекле саклана: буйругыма [18r], дошманларыма [19v], қаныма [34v], күзүңә [18r], хидмәтинә [17v], варисларына [19v] һ.б.

Тартымсыз төрләнештә غا – *-ға/-гә,* کا – *-кә* (нигездә кушылып, ә قا – *-қа* аффиксы сүзләрдә һәрвакыт аерым языла: ترکستانغا [92r10], هندوستانغا [92r10], التونغا [92r12], رومکا [92v6], یمنغا [92v9] һ.б.

Күзәтүләрдән күренгәнчә, юнәлеш килешнең *-қа* саңгырау вариантының «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Хөсрәү вә Ширин» телендә күпчелекне тәшкил итүе, традицион әдәби тел нормаларының (уйгыр-кыпчак) эзлекле саклануы турында сөйли. «Гөлестан бит төрки», «Кисекбаш китабы», «Җөмҗөмә солтан» истәлекләрендә юнәлеш килеше кушымчалары нигездә саңгыраулыкта-яңгыраулыкта яраша, тартымсыз төрләнештә кыпчак төрләнеше норма булып тора. Угыз телләре өчен хас булган *-а/-ә* сирәк теркәлгән. Чагыштыр: «Мәхәббәтнамә» истәлегендә юнәлеш килешенең *-а/-ә* формасы – 10 мәртәбә,

*-қа/-ға* варианты 6 мәртәбә кабатлана, «Кисекбаш китабы»нда *-а/-ә* – 15 мәртәбә, *-қа/-ға* кушымчасы исә 90 тапкыр кабатлана.

III зат тартымлы төрләнештә *-н* + *-ға, -н* + *-а, -ы* + *-ға* юнәлеш килеш формалары теркәлгән. «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Хөсрәү вә Ширин» текстларында *-н* + *-ға,* ягъни уйгыр-кыпчак төрләнеш тибына нигезләнгән. «Гөлестан бит төрки», «Мәхәббәтнамә», «Җөмҗөмә солтан», «Кисекбаш китабы»нда *-н* + *а* төрләнеш тибы эзлекле саклана. «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис» текстларында *-н* + *ға, -ы* + *ға* вариантлары кулланылган. Тартымсыз төрләнештә юнәлеш килеш кушымчалары – аерым, тартымлы төрләнештә исә кушылып язылган.

*Төшем килеше.* «Кыйссасел-әнбия» текстында төшем килеше һәр очракта *-ны/-ни* кушымчалары белән тәгъбир ителә: Салихны [А.15.20], мәликләрни [А.7.10], ишни [А.12.12], ташны [А.8.1], хатунны [А.14.19], малымызны [А.8.3], ириңни [А.9.2] һ.б.

Тартымлы төрләнештә *-ын, -ыны* вариантлары теркәлгән, 14 бит күләмендә уздырылган статистик исәпләүләрдән күренгәнчә, *-ын* варианты –15 мәртәбә, тулы варианты *-ыны* 6 мәртәбә кабатланган.

Килеш кушымчасы тартымсыз исемнәрдә нигездә – аерым, тартымлы төрләнештә кушылып язылган: جهان نى – җиһанны [А.17.9], حام نى – хамны [А.6.15], تاجينى – тажҗыны [А.10.17], تونين – тонын [А.11.7] һ.б.

«Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә төшем килешенең نى – *-ны/-ни* кушымчалары теркәлгән:қапыңны ачғыл [126], чәтүкни ивендин чығарды [312.10], табибны ивинкә алатыр [293.10] һ.б.

Тартымлы төрләнештә *-ын, -ыны* вариантлары теркәлгән, *-ыны* угыз формасы норма булып тора: ул дарахатның улулуқыны тәқы күркүни тәқы йашыллықыны һичким әрсә сифат қылу билмәгәй [319.8], бу отнуң күлләрини җүмләсиниң көзләринкә тулдурды [218.9], күзләрин йумқайлар [158.3] йүзүн кәмәшкәй [336.15] һ.б.

Төшем килешенең نى – *-ни* кушымчасы нигезгә ялганган: مالنى – малны [80.3], كوركين – күркин, 6 [4.11], اولوغ لارين – улуғларын [80.5] һ.б.

«Җөмҗөмә солтан» истәлегендә төшем килешенең نى – *-ны/-ни* кушымчалары теркәлгән: җиһанны [25], йарлыны уә байны [39], сүзни [33] һ.б.

I зат һәм II зат тартымлы исемнәрдә *-ны* кыпчак тибы норма булып тора, төшем килешенең *-и* формасы сирәк очрый: сәләмимни [2], қул қырнақларымны [7], һәлими әйдәм [23] һ.б.

III зат тартымлы төрләнештә *-ын, -ыны* вариантлары теркәлгән, *-ын* формасы норма булып тора (26 сүзформа). *-ыны* 11 мәртәбә

теркәлгән: тупрақын [10], җаныны [37], күңлини [14], күзләрин [4] ~ күзләрини [43] һ.б.

«Кисекбаш китабын»да төшем килешенең *-ны* варианты 16 мәртәбә кабатлана, *-и* формасы белән чагыштырганда күпчелекне тәшкил итә, 3 очрак теркәлгән: хақны [3], башны [35], ғаләмни [166], башла Ғали сүзи [11], қылмамыш ирди хәир эши [156], оғлымны [65], күзләримни [68] һ.б. Тартымлы төрләнештә *-ын, -ыны* вариантлары теркәлгән, *-ын* варианты 19 мәртәбә, тулы варианты *-ыны* 13 мәртәбә кабатланган: йүзин [21, 126] ~ йүзүн [31], сүзин [22], қайғысын [205, 208], йирини [136], башыны [176, 219] һ.б.

Тартымлы һәм тартымсыз төрләнештә төшем килеше кушымчалары кушылып язылa: حقنى – хақны [3], باشنى – башны [35], عالم نى – ғаләмни [166] һ.б.

«Хөсрәү вә Ширин» текстында төшем килеше һәр очракта *-ны/ -ни* кушымчалары белән тәгъбир ителә: сарайны [20r], мәйданны [18r], йирни [18r], сөзни [18v], айны [24r [0]] һ.б. *-и* очрагы сирәк, бары 3 мисалда теркәлгән: сәләми айтып [83v], бойурды кем қопарың бир сарайы таба көр бир йаман исиг һаайы [26r] һ.б.

Тартымлы төрләнештә *-ын, -ыны* вариантлары теркәлгән. *-ын* варианты (а) – 44 мәртәбә, *-ыны* тулы варианты (ә) 19 мәртәбә кабатлана:

а) сөзин [18 r, 21v], башын [21v], йүзин [23v], етәгин [18v], йашын [19r], ақлын [19v], қулақын [22v] һ.б.;

ә) нақшыны [19r], күңлини [23v], күзини [23v], йүзини [23v], сүзини [20r], илгини [24v], сууыны [22 r] һ.б.

Төшем килеше кушымчалары нигездә кушылып язылa, аерым язылган очраклар шактый сирәк: التون نى – алтунны [29 r], قول لارنى – қулларны [104v], هومايوننى – һомайунны [104v], كيشي نى – кишини [88 r] һ.б.

«Мәхәббәтнамә» текстында төшем килеше *-ны/-ни/-и* кушымчалары белән тәгъбир ителә. Тартымсыз төрләнештә *-ны* формасы – 62 мәртәбә, ә көньяк төрләнешкә хас *-и* варианты 3 мәртәбә кабатлана: изни көрмәк үчүн [260], сүйүрмүн күзни [260], ғаләмни өртәр [258, 245, 232, 158] җәфаны [255, 165], халқны [253] һ.б.

*-и:* сәлами [129], китаби [38], әйами [37] һ.б.

I зат, II зат тартымлы исемнәрдә төшем килешенең *-ны/-ни* күрсәткече генә очрый: әхвәлимни [431], көзүмни [138], сәламимни [132, 131, 130], иманымызны [425], җанымызны [425] һ.б.

III зат тартымлы төрләнештә *-ын, -ыны* вариантлары теркәлгән, *-ын* варианты – 37 мәртәбә, тулы варианты *-ыны* 13 мәртәбә

кабатланган: сүзин [437], топрағын [277], нурын [245], бабын [62], җәмалын [47] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки» текстында төшем килеше һәр очракта *-ны/-ни* кушымчалары белән тәгъбир ителә: Йосыфны [20r], сүзни [25v], кишини [36r], илимни [28 r], хатириңни [19 r] һ.б. III зат тартымлы төрләнештә *-ын, -ыны* вариантлары теркәлгән, *-ын* формасы норма булып тора: атасын [33 r], йазықын [34 v], йүзүн [33 r], башыны [48 v], ләшкәрини [22 v] һ.б.

Тартымсыз төрләнештә төшем килеше кушымчалары аерым язылган: عراب نی [119v1], كونكول نی [118v7] һ.б. Тартымлы төрләнештә төшем килеше кушымчаларының нигезгә ялгануы норма булып тора: ايلمنی [117r10], وقتين [93r6], ايلين [93в3] һ.б.

Күзәтүләрдән күренгәнчә, төшем килешенең *-ны/-ни* варианты барлык истәлекләр телендә эзлекле саклана, тартымсыз төрләнештә норма булып тора. Угыз телләре өчен хас булган *-и* сирәк теркәлгән. Чагыштыр, «Мәхәббәтнамә» төшем килешенең *-ны* формасы – 62 мәртәбә, *-и* варианты 3 мәртәбә кабатлана, «Кисекбаш» әсәрендә *-ны* – 16 мәртәбә, *-и* кушымчасы исә 3 тапкыр теркәлгән. III зат тартымлы төрләнештә *-ын* һәм *-ыны* формаларының истәлекләр телендә вариатив кулланылышы теркәлгән, *-ын* формасы ешрак кабатланган, бу факт исә истәлекләр телендә кыпчак әдәби тел нормаларының саклануын күрсәтә.

*Чыгыш килеше.* Чыгыш килеше тикшерелә торган истәлекләрдә ике төрле вариантта килә. Борынгы уйгыр әдәби теленнән килә торган دين *-дин* варианты Алтын Урда чоры язма истәлекләре өчен норма буларак билгеләнә, фәкать «Гөлестан бит-төрки» текстында чыгыш килеше һәр очракта –дан кушымчасы белән тәгъбир ителә. Мисаллар:

«Кыйссасел-әнбия»: دين – *-дин*, تين – *-тин:* хақдин [5.9], алтундин [7.3], халықтин [17.11], көкдин [19.5], тәңриләримиздин [12.15], тәңриңдин [12.17] һ.б. III зат тартымлы төрләнештә чыгыш килеше кушымчаларында этимологик *-н-* саклана: ыруыңдин [6.6], йығачындин [7.7], йапурақындин [11.16] һ.б.

*-н-* авазыннан башка кулланылган ике очрак теркәлгән: бодуныдин [5.19], зинданыдин [9.5]. Тартымсыз төрләнештә кушымчалар аерым да, кушылып та язылган: زعفران دين – зәғфран дин [9.15], تنكری دين – тәңридин [12.15], قبوغ دين – қабуқдин [7.11], كيشی دين – кишидин [11.18], التون دين – алтун дин [7.7] һ.б.

Тартымлы төрләнештә чыгыш килеше кушымчалары нигездә кушылып язылган: زنداندين – зинданыдин: [8.14], يغاجيندين – йығачындын [7.7], يبورغاقيندين йапурақындин [17.19] һ.б.

«Нәһҗел-фәрадис»: دين – *-дин:* Миср халқы бирлә Мәдинәдин чықтылар [136.6], анда сууы йаруқ турур тышындин ичи көрнүр ичиндин тышы көрнүр [314.7], күндин күн казғусы зыйада болды [233.15], бир йирдин бир йиргә бармақ [229.10] һ.б.

Тартымсыз төрләнештә кушымчалар аерым язылган, кушылу очраклары сирәк: كوموش دين – күмүшдин [64.5], ياقوت دين – йақутдин [64.11], التون دين – алтундин [64.14] һ.б.

«Җөмҗөмә солтан»: دين – *-дин,* сирәк تين – *-тин:* күндин [69], башдин [21], йирдин [43], утдин [17] ~ уттин [3], һақдин [2], сиһәттин [2] һ.б.

III зат тартымлы төрләнештә чыгыш килеше кушымчаларында этимологик *-н-* саклану норма, төшеп калган очраклар сирәк: ниғмәтиндин [11], башындин [34], әлиндин [17], малыдин [29], сачыдин [14].

«Кисекбаш китабы»:دين *-дин:* аузындин [172], Кисикбашдин [102], йириндин [38], йүзиндин [29] һ.б.

Чыгыш килеше кушымчалары кушылып язылган: كسوك باشدين – кисикбашдин [102], يرمدين – йеримдин [46], يريندين – йериндин [38], ايلينكدي – әлиңдин [174], يوزندين – йүзүндин [29] һ.б.

«Мәхәббәтнамә» әсәрендә чыгыш килешнең دين – *-дин,* сирәк تين – *-тин,* دان – *-дан,* دن – *-дән* вариантлары теркәлгән. Борынгы уйгыр әдәби теленнән үк килә торган دين – *-дин* варианты – 79 мәртәбә, хәзерге татар теле өчен хас булган دان – *-дан,* دن з – *-дән* вариантлары 4 мәртәбә кабатлана: көнүлдин [19] йилдин [69], көздин [100], дудағындин [277], күзүндин [163], қылычындин [92], дошманымыздин [367]; دان : җандан [56], сәргәрдән [52]; хандан [54], йаздан [53].

Саңгыраулыкта-яңгыраулыкта ярашу эзлекле сакланмый: топрақдин [7], ташдин [8], башдин [115, 132], мәхаббәтдин [171], Мөхәммәдтин [181] һ.б.

III зат тартымлы төрләнештә чыгыш килеше кушымчаларында этимологик *-н-* 12 очракта сакланган, төшеп калган очраклар 10 мәртәбә теркәлгән:

а) топрақындин [335], йолындин [374], әлгиндин [364], әлиндин [380], арзусындин [251] һ.б.;

ә) йарыдин [371], ишиндин [227], аймышларыдин [166], ишләридин [166], нурыдин [156], йашыдин [119], инҗүсидин [112], күчидин [72] һ.б.

«Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә чыгыш килешенең борынгы уйгыр әдәби теленнән үк килә торган دين *-дин* варианты норма булып тора, دان , دن варианты бары өч мисалда сакланган: қайғудин [20r], қолдин [21v], йолдин [21v], арсландан [22v], нардан [18 r] һ.б. Чыгыш килеше кушымчалары аерым да, кушылып та язылган: كونكلوم دين – көңлүмдин [1v], قموغ دين – қамуғдин [9v], سبب دي– сәбәбдин [47v], قياش دين – қайашдин [109 r], ايشدين – ишдин [2v], تاشدين – ташдин [64v] һ.б.

III зат тартымлы төрләнештә чыгыш килеше кушымчаларында этимологик *-н-* һәр очракта сакланган: атындын [21v], йүзиндин [22r0], тәхтендин [21r], йериндин [21v], елиндин [19r 0], көркүндин [18v] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки» әсәрендә чыгыш килешнең دان *-дан* / دن *-дән* вариантлары теркәлгән, III зат тартымлы төрләнештә чыгыш килеше кушымчаларында инфикс *-н-* һәр очракта сакланган: ирдән [18r], ишикдән [19r], кишидән [36r], дошманыңдан [36 r], башымдан [74v], илиңдән [67v], тилиндән [27r], йимектин [62v], хикмәттин [59r] һ.б.

Чыгыш килеше кушымчалары норма буларак аерым язылган: حلب دان [92v], عالم دان [119r], تنكرى دان [93v], حالدان [119r] һ.б.

Чыгыш килешенең борынгы уйгыр әдәби теленнән килә торган دين – *-дин* варианты Алтын Урда чоры язма истәлекләре өчен норма буларак билгеләнә, фәкать «Гөлестан бит-төрки» текстында чыгыш килеше һәр очракта *-дан* кушымчасы белән тәгъбир ителгән.

«Кыйссасел-әнбия» әсәрендә урын-вакыт килеше *-да/-дә* кушымчасы белән белдерелә: қапуғда [18.16], йирдә [17.20], сәғәтдә [9.8], көлдә [13.4], қапуқымда [10.11], иләкимиздә [13.1], ивиңдә [16.18] һ.б.

III зат тартымлы төрләнештә урын-вакыт килеше кушымчаларында инфикс *-н-* һәр очракта сакланган: йириндә [5.2], көңлиндә [8.15], иүүндә [8.18], йығачында [9.17] һ.б.

Тартымсыз төрләнештә кушымчалар аерым язылган, кушылу очраклары сирәк: زندان دا[8.12] , ساعت دا [9.8],آى دا [9.19], كافرليق دا [11.20], تاغ دا [13.2]. Тартымлы төрләнештә урын-вакыт килеше кушымчасы һәр очракта нигезгә кушылып язылган: قبوغومدا[10.9], قيزلاريمدا [15.5], يريندا[5.19], كونكليندا [8.15] һ.б.

«Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә урын-вакыт килеше *-да/-дә* кушымчасы белән белдерелә, саңгырау варианты *-та/-тә* сирәк теркәлгән: йитинч қат көкдә қойдылар [35.5], сахрада [340.16], күкдә [38.5], мүгүшдә [12.1]; *-та/-тә:* хақиқәттә [312.17], уғлаймышта [341.7], утта [145.1] һ.б.

III зат тартымлы төрләнештә урын-вакыт килеше кушымчаларында инфикс *-н-* һәр очракта сакланган: йил башларында [305.1], күңлүңдә [302.6], Мәдинә шәһриндә [113.14], башы қатында [235.15], тау башында [15.16] һ.б.

«Җөмҗөмә солтан» әсәрендә урын-вакыт килеше *-да/-дә, -та/-тә* кушымчалары белән белдерелә: йақасында [А.15б], иңиндә [А.22а], утта [33] һ.б.

III зат тартымлы төрләнештә урын-вакыт килеше кушымчаларында инфикс *-н-* һәр очракта сакланган: йир йүзиндә [28], ғүмриндә [21], *-н-* авазыннан башка кулланылган бер мисал теркәлгән: ким Миср шәһридә [8].

«Кисекбаш китабы»нда урын-вакыт килеше *-да/-дә* күрсәткече белән тәгъбир ителә, кушымчалар нигезгә ялганып языла: قيوغده – қуйуғда [232], اوستومزده – үстүмүздә [3], عمرنده– ғүмүрүндә [156], ير يوزنده – йер йүзүндә [53] һ.б.

*Урын-вакыт килеше.* Тикшерелгән чыганакларда урын-вакыт килеше *-да/-дә* кушымчасы белән белдерелә, саңгырау варианты *-та/-тә* сирәк теркәлгән.

«Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә урын-вакыт килеше *-да/-дә* кушымчасы белән белдерелә, саңгырау варианты *-та/-тә* сирәк теркәлгән, кушымчалар нигезгә ялганып языла: باغ دا [27r], خاتوندا [54r], اوطدا [54r], ملت دا [77v], ايشيكيندا [88 r]; әләмдә [22v] чәшмәдә [25 r] һ.б.

*-та/-тә:* сәғәтта чықмышбыз [21 r], отта [2v], һалүәттә [44 r] һ.б. III зат тартымлы төрләнештә урын-вакыт килеше кушымчаларында инфикс *-н-* һәр очракта сакланган: түшиндә [19v], йақасында [24v], күңлиндә [22v], вақтында [23 r] һ.б.

«Мәхәббәтнамә» һәм «Гөлестан бит-төрки» әсәрләре телендә урын-вакыт килеше دا – *-да/-дә*, تا – *-та/-тә* формалары белән тәгъбир ителә.

«Мәхәббәтнамә»: алты күндә [4], аҗунда [34], қыш уртада [82], ағызда [136], йолда [152], сөздә [173] ~ сөзтә [382], көктә [124], чәриктә [72], тәнимдә [437, 362, 230, 286], қатымда [36], йүзүңүздә [248], сүзүңдә [347], ғыйшқында [237], йолында [344] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки»: йирдә [17v], виләйәтдә [39v], қууәтдә [39r] ортамызда [27r], көңлүндә [18r] һ.б.

*Корал килеше. -ын/-ин, -ун/-үн* кушымчалы корал килеше борынгы төрки язма традициянең сакланышы буларак аерым очракларда Алтын Урда язма истәлекләре телендә кулланылган. Мәсәлән: шәрбәт

бәрдиләр әрсә билди ичмәди күчүн ичүрдиләр [НФ. 196.17]; ол уақтын оҗмахта әрдим [НФ. 37.17], имамдин астын абдаст қылды [НФ. 222.2]. Түрт йанымга бақтым һич кем әрсәне көрмәдим үстүн бактым әрсә көрәрмән [НФ. 9.7]; әй йигит йақын килгил [НФ. 202.12]; ташы ойнар үәли ич зарын йығлар [ХШ. 113v], өз әлгин башынға топрақ сачты [ХШ. 48v]. Корал килешенең гомумән бу чор язма истәлекләрендә сирәк кулланылуын, ә корал килеше мәгънәсенең истәлекләрдә *белән* бәйлеге ярдәмендә белдерелүен күрәбез.

*-ча/-чә кушымчалы охшату-чагыштыру килеше.* Борынгы төрки нигез телдә охшату-чагыштыру килеше әдәби тел традициясе буларак сакланган, Алтын Урда чорында язылган истәлекләр телендә чагыштырмача сирәк очрый. Мисаллар: мәним артымча тәрк кәлиң [НФ. 36.5]; Мөхәммәд ... дәрйа қырығыңа кәлде йаранлары бирлә тәқый артынча Фәрғун кәлде [НФ. 75.6]; оланлар артынча таш аталар [НФ. 400.7]; йулда хәтеренгә түште ким кәчкә Мәдинә йулынча барсам Мустафаға тәқый зийарат қылсам [НФ. 180.17]; йети дәрйаны бир көлчә йүзәр ол [ХШ. 13v]; қылып буғдай иңим арпача сарығ [ХШ. 48v]; итчә саным йоқ [ХШ. 66v] һ.б.

*-ра/-рә* кушымчалы юнәлеш килеше нигездә борынгы төрки язма истәлекләр теле өчен хас. Алтын Урда чоры әдәби әсәрләр телендә *тышра, ичрә, үзрә, соңра* кебек аерым сүзләрдә кабатланып кулланыла: бир аҙақыны эвгә қайтты тәқый бир аҙақы тышра турур [НФ.360.13]; Йосыф пәйғамбәр Зөләйха бирлә ичрә қалды [НФ. 360.9, 215.14. 391.17]; бу тәхет бирлә һава үзрә йүрмәк тиләсә [НФ. 210.8]; андин соңра Госман хәлифә болды [НФ. 78.3, 7.10, 81.16, 85.14,147.7] һ.б. Бу чор истәлекләр телендә алар килешкә хас грамматик мәгънәне югалту процессын кичереп, рәвеш сүз төркеменә хас билгеләргә ия булалар. Чагыштыр: ичрәрәк қопарғыл, бады тәқый тамыны йықты тәқый ичрәрәкдин қопарды [НФ. 224.14].

Алтын Урда чоры әдәби әсәрләре телендәге төрле килеш формаларының кулланылыш чагыштырмасын өйрәнү шул чорда традицион әдәби телгә хас уйгыр-кыпчак төрләнеш тибыннан гомумхалык сөйләм теленә хас кыпчак тибына күчешне , кыпчак теленә хас нормаларның өстенлек алуын раслый.

Уйгыр-кыпчак төрләнеше Насретдин Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия», Мәхмүд әл-Болгариның «Нәһҗел-фәрадис», Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрләрендә өстенлек алган.

Тартымсыз төрләнеш

| Килешләр | «Кыйссасел-әнбия» | «Нәһҗел-фәрадис» | «Хөсрәү вә Ширин» |
|---|---|---|---|
| Баш килеш | Ø | Ø | Ø |
| Иялек килеше | -ның/-нуң | -ның/-нуң | -ның/-нуң |
| Төшем килеше | -ны | -ны | -ны |
| Юнәлеш килеше | -қа/ -ға | -қа/-ға | -қа/-ға |
| Чыгыш килеше | -дин | -дин | -дин |
| Урын-вакыт килеше | -да | -да/-та | -да |

Тартымлы төрләнеш

| Килешләр | «Кыйссасел-әнбия» | «Нәһҗел-фәрадис» | «Хөсрәү вә Ширин» |
|---|---|---|---|
| Баш килеш | Ø | Ø | Ø |
| Иялек килеше | -ның/-нуң | -ның/-нуң | -ның/-нуң |
| Төшем килеше | -ын | -ыны | -ын |
| Юнәлеш килеше | -нға | -нға | -нға |
| Чыгыш килеше | -ндин | -ндин | -ндин |
| Урын-вакыт килеше | -нда | -нда | -нда |

Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» һәм «Кисекбаш» әсәрләре теле кыпчак төрләнеш тибына нигезләнгән, бары чыгыш килешендә генә традицион *-дин* кулланылган.

Тартымсыз төрләнеш

| Килешләр | «Гөлестан бит-төрки» | «Мәхәббәт-намә» | «Җөмҗөмә солтан» | «Кисекбаш китабы» |
|---|---|---|---|---|
| Баш килеш | Ø | Ø | Ø | Ø |
| Иялек килеше | -ның | -ның | -ның | -ның |
| Юнәлеш килеше | -ға | -ға | -ға | -ға |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Төшем килеше | -ны | -ны | -ны | -ны |
| Чыгыш килеше | -дан | -дин | -дин | -дин |
| Урын-вакыт килеше | -да | -да / -та | -да | -да |

Тартымлы төрләнеш

| Килешләр | «Гөлестан бит-төрки» | «Мәхәббәт-намә» | «Җөмҗөмә солтан» | «Кисекбаш китабы» |
|---|---|---|---|---|
| Баш килеш | Ø | Ø | Ø | Ø |
| Иялек килеше | -ның | -ның | -ның | -ның |
| Юнәлеш килеше | -на | -на | -на | -на |
| Төшем килеше | -ын | -ын | -ын | -ын |
| Чыгыш килеше | -ндан | -ндин | -ндин | -ндин |
| Урын-вакыт килеше | -нда | -нда | -нда | -нда |

Аерым килеш формаларында вариатив кулланылган, азчылыкны тәшкил иткән килеш күрсәткечләре килешләр системасының үсеш-үзгәреш закончалыкларын абайларга мөмкинлек бирә.

Тартымсыз төрләнеш

| Килешләр | «Кыйссасел-әнбия» | «Нәһҗел-фәрадис» | «Хөсрәү вә Ширин» | «Гөлестан бит-төрки» | «Мәхәб-бәтнамә» | «Җөмҗөмә солтан» | «Кисекбаш китабы» |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Иялек килеше | – | – | – | – | – | -иң | – |
| Юнәлеш килеше | – | – | -а | -а | -а | -а | -а |
| Төшем килеше | – | – | – | – | -и | – | -и |
| Чыгыш килеше | – | – | -дан | – | -дан | – | – |
| Урын-вакыт килеше | – | – | – | – | – | – | – |

Тартымлы төрләнеш

| Килешләр | «Кыйссасел-әнбия» | «Нәһҗел-фәрадис» | «Хөсрәү вә Ширин» | «Гөлестан бит-төрки» | «Мәхәббәт-намә» | «Җөмҗөмә солтан» | «Кисекбаш китабы» |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Иялек килеше | – | – | – | – | – | – | – |
| Юнәлеш килеше | -ы-ға<br>-н-а | -ы-ға<br>-н-а | -н-а | – | – | -ы-ға | – |
| Төшем килеше | – | -ы-н | -ы-н | -ы-н-ы | -у-n-у | -ы-н-ы | -ы-н-ы |
| Чыгыш килеше | -ы- дин | – | – | – | -ы- дин | -ы- дин | – |
| Урын-вакыт килеш | – | – | – | – | -ы- да | -ы- да | – |

Күзәтүләрдән һәм китерелгән таблицалардан күренгәнчә, килешләр системасының нигезендә кыпчак формалары ята. Традицион формалар (уйгыр, угыз формалары) вариатив кулланылган, базис төрләнешне тәшкил итми, әмма угыз формалары борынгы уйгыр теленә хас формаларга караганда ешрак очрый: *-а* («Хөсрәү вә Ширин», «Гөлестан бит-төрки», «Мәхәббәтнамә», Җөмҗөмә солтан»), *-и* («Мәхәббәтнамә», «Кисекбаш китабы»), *-дан* («Җөмҗөмә солтан», «Мәхәббәтнамә»).

XIV–XV гасыр Алтын Урда чоры әдәби әсәрләр телендә ике төрләнеш тыбының – традицион әдәби телгә хас уйгыр-кыпчак төрләнеше һәм гомумхалык сөйләм теленә хас кыпчак төрләнешенә хас нормаларның булуы билгеләнә.

## 2.2. Сыйфат

Күренешләргә җанлылык бирүдә сыйфат сүз төркеменең роле зур. Язучылар тирән кичерешләрне, тормыш күренешләрен күп төрле алымнар, образлы сурәтләү чаралары, сыйфатлар ярдәмендә тасвирлый. Алтын Урда чорында язылган әдәби әсәрләр телендә төрки-татар, гарәби һәм фарсы чыгышлы сыйфатлар кулланыла. Әдәби истәлекләрдә әйбер һәм күренешләрнең төсен белдергән сыйфатлар,

кешенең характерын билгели торган лексик берәмлекләр күпчелекне тәшкил итәләр. Әсәрдә төсне белдергән قزيل – *қызыл*, قرا – *кара*, اق – *ак*, ياشيل – *йәшел*, ساري – *сары* ~ سارغ – *сарығ*, الا – *ала* сыйфатлары туры һәм күчерелмә мәгънәләрдә кулланылган.

Насретдин Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия» текстында төсне белдереп килгән сыйфатлар төп мәгънәдә теркәлгән. Мәсәлән: қызыл: сизләрдә бир қызыл йүзлүк сарығ сачлығ ким ерсә бу тевәни өлтүргәй [А14.6, Б69.2]; инкән чықарғыл қызыл түклүк тили қара [А13.5]; тәхт қылдурды қызыл алтундын [А15.7, Б70.17];

«Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә предметның төсен белдергән қызыл, кара, ақ, йәшел, сарығ, ала кебек төрки чыгышлы сыйфатлар килә, җөмләдә күбрәк исем белән белдерелгән җөмлә кисәген ачыклап, аергыч була, ярдәмче фигыльләр белән килеп хәбәр дә була. Мисаллар:

قزيل – *қызыл*: сахрада Ғиззи атлығ қызылтәпә бар [155.3]; бәғзиләри ақ мәүәләр турур тәқи бәғзиләри қызылмәйүәләр туруртәқи бәғзиләри сарығ мәүәләр турур [319.10]; бу ақ мәхәсиним қызыл қанға бойалса [153.6], әкәгү тәқи қызыл көмлек кимиш әрдиләр [177.5]; биш йүз қызыл алтун [256.3];бир муғаззам сарайқызыл алтундин [64.13], бучуқ батман қызыл алтун биргил [97.7]; Бәйтүл. Мәғмүр ев әрди қызыл йақутдин әрди [37.14]. Текстта қызыл сыйфаты төсне белдерүдән тыш, затлы металл – алтын, кыйммәтле ташлардан – якут сүзләре белән янәшә кулланылып, байлык, затлылык, кыйммәтлек төшенчәсен дә белдерә.

اق – *ақ*: уштмахдин бир ақ таш кәлтүрди [38.12]; ақ қушлар турур [42.17]; бәғзиси ақ тонлуғлар бәғзиси ала тонлуғлар [55.1]; ақ тон кәҙмиш [102.5]; мәликниң ақ сачыны тәмуғ утынға харам қылғыл [317.3];

Җөмләдә *ақ* сыйфатының гарәп телендәге синонимы шәрехләү юлы белән белдерелгән: Бер ғәрәб теленчә әййәмүл.бейаз ақ күнлер темәк болур. Бу үч күннүң кечеләри йаруқ булған үчүн бу күнләркә әййәмүл. бейаз тип айдылар [282.9, 10]

الا – *ала*: ол ала тунлуғларқа дәстур болмады әрсә анлар кирү билмәдиләр [56.16]; ала атлығ ақ тунлуғлар адами суратынға килдиләр [72.16];

قرا – *қара*: бир қара килим бар әрди [144.1]; өзи йигит киши турур қара тонлуғ [148.16]; бир өртүңи қара килим алдылар [159.8]; қараңқу түн ичиндә қара таш үзәсиндәки қарынчаның тепренгенини көрәр [229.13]; бу ғәләм ичиндә қара йер болса әрди [378.11]; қара йер үзрә йатмақ [395.15];

سارغ – *сарыг*: қорқған кишиниң йүзи сарығ керек [233.5]; тәни арығ йүзи сарығ арқасы бүкрәрмиш [274.16]; көзләрендин сарығ сув ақғай [267.13]; йүзи сарығ болмыш [148.16] һ.б.

یاشل – *йашыл*: бу ики қапуғ йашыл зүммүрүддин әрди [37.16]; бабам Әбузарны түшүмдә көрдүм бир йәшил чимгән ичиндә болур ол чимгән ичиндә йашыл тон кизип Қөр'ән оқуйур [131.14]; ол турбат үзрә йашыл қубба қопарды [156.6] һ. б.

جقر – *чақыр*: чақыр көзлүг болғай [399.5].

Сыйфатланмышы төшеп калып исемләшү очраклары – сирәк күренеш: қол арасындин бир қара күринди [71.13]; аның сарығлықынға бақған тәғәжҗүб қылур [340.14] һ.б.

Аерым очракларда, ярдәмче фигыль белән килеп, хәбәр функциясен башкарырга мөмкин: мәхәсини қара турур [23.4]; рәнги ақ турур [53.4]; бақармән бир шахс бар мәһасини йарысы ақ турур йарысы қара турур [54.16]; сачы тәқи мәхәсини җүмлә ақ әрмиш әрди [56.7]; тонлары ақ болур [55.2]; тәни арығ йүзи сарығ арқасы бүкрәрмиш [274.16]; бу инәкниң рәңги сарығ турур һ.б.

Төс белдергән сыйфатларның дәрәҗә белән төрләнүе теркәлгән. Артыклык дәрәҗәсе кабатлау юлы белән белдерелә: ол ақ ақ таш қап қара болды [38.15]; сап-сарыг болмыш [148.16]; чагыштыру дәрәҗәсе: ичиндәки сув сүтдин ақ турур ғәсәлдин сүчүг турур [62.6]; оқдин қатығрақ ақар тәқисувы сүтдин ақрақ турур [57.7]; кимлек дәрәҗәсе: бу инәкниң рәңги сарығ турур вәликин қарамтул сарығ турур [340.14].

Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәрендә төсне белдерү өчен қызыл, кара, ақ, йәшел, сары, көк сыйфатлары кулланылган. Мисаллар: һилғәтин кәйдүрүп илләринә қызыл, ақ, сары чичәкләр биргәй [3б.1]; билән китәр ми ләүни қара көмүрдән [15а.7]; фәрши көк мәрмәр [150а.7]; қылып көк от қызыл гөл бирлә сохбәт [80б.11]; йашыл атлас бисат төшәгәй [3а.11]; йашыл сахрада қуйны бир мүсүлман хәлаш итти [68б.11]; бир ақ сакаллы хоҗа мини евинә қонақ итти [135а.1] һ.б.

Текстта *қара* сыйфатының төрле мәгънәгә ия булуы ачыкланды. Мәсәлән, белемсез, надан мәгънәсе: бир қарақолы бар иди иңкән биликсиз [46б.13]; төрки һәм фарсы алынмасы (зәнги) синоним буларак кулланыла: бир қара зәңги фәррашқа бирди [47б.6]; ул қара див чәһрәли қолның [47б.9] һ.б.

Гомумхалык сөйләм теле өчен хас булган *сары* язылышы гына бирелгән, «Гөлестан бит төрки» текстында башка вариантлар теркәлмәгән.

«Хөсрәү вә Ширин» поэмасында төс белдергән лексемалардан *сары, ал, қара, ала, ақ, көк* сыйфатлары кулланылган: сарығ алтун түкәл ғәләм қа сачты [20v]; сарығ гүл солды [70 v] һ.б. Мисалларда борынгы төрки теле традициясе буенча һәр очракта сүз ахырында увуляр ғ авазы сакланган.

Текстта *ал*, *ақ*, *көк*, *ала* сыйфатлары актив кулланылган, фарсы алынмасы *зәңги* сирәк очрый: әдүқдә қылма ал мәңизиңни сарығ [48v]; солуб сарғарды мунтег ал чичәгим [26r]; аның ол ал чичәк иңәки солды [68r]; бу хәсрәт бирлә солду ал йаңақым [24r]; көзин дин йаш йиринкә ақты ал қан [50v]; гәхи ол күмүш һәм тег ақ сақақын [47r]; ақ көзлүг тевәләр [101v]; қонуб көк чимгән үзрә [27v]; түн күн ала ат тәг йүгрәр талмаз [50r]; бири сарығ, бири ақ, бири зәңги [14v], аҗундин қачты зәнгиләр сипахы [51v] һ.б.

*Кара* сыйфаты күп очракта «төн» сүзенә бәйләнеп килгән: аҗун толды йаруқ китти қара түн [15r]; йаруқлуқ көрдисә қачты қара түн [35r]; йана арслан тег ат рәнги қара түн [23r]. Язучы қара һәм ақ сыйфатларын капма-каршы куюю өчен кулланган: қара киш тег сач вә ақ ас тег әндәм [22r].

«Мәхәббәтнамә» әсәрендә авторның сыйфатлар белән иркен эш йөртүен күрергә мөмкин. Төсне белдергән сыйфатлардан *қара*, *ал* берәмлекләре еш кулланылган: қара кирпүкүңғә күндүз тиңалмас [50]; җеһан тутты қара топрақдин сүнбүл төрәтти [27]; қара миң ал йәңақында йәрашур [36 – 106]; аның кем ал иңендә [27] һ.б.

«Җөмҗөмә солтан» дастанында кулланылган төсне белдергән дүрт сыйфатның өчесе – «кара»: бу қара йир, кем күрәрсән, туп-тулуғ [157.38]; бу қара тупрақ эчендә ничәләр [158.4]; ике сурәт: бере күк, бере қара [164.16]. Соңгы мисалда сыйфатлар хәбәр функциясендә килгәннәр.

«Кисекбаш китабы», гомумән, сыйфатларга бай түгел. Истәлектә бердәнбер төс белдергән сыйфат теркәлгән: сақалы ақ һәм йүзиндин нур ақар [137.22]

Әлеге мисаллардан күренгәнчә, әсәрләрдә төс белдергән сыйфатлар чикле: қызыл, кара, ақ, йәшел, сарығ, ала, көк, чақыр. Язучылар яратып куллана торган «қара» сыйфаты күп мәгънә төсмерләренә ия.

Тәм ягыннан билгене белдергән сыйфатлар чагыштырмача аз санлы, нигездә تاتلي – *татлы* ~ تاتليغ – *татлыг*, *ачы*, شيرين – *ширин*, سوجوك – *сүчүг* сыйфатлары кабатланып килгәннәр.

*Татлы* сыйфатының график рәвештә әдәби әсәрләр телендә аерымлануын ачык күрергә мөмкин. Насретдин Рабгузинең «Кыйссасел-

әнбия, Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрләрендә традицион орфографик норманың саклануы (татлығ), Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәрендә сөйләм теле тәэсирендә *татлы* язылышы, Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында вариатив язылыш чагылыш таба.

Чагыштыр:

«Кыйссасел-әнбия»дә: мундағ татлығ йемишим йоқ [Б.11–20]; НФ: ғәсәлдин сүчүг турур тәқи йызығы йыпардин татлығ турур [62-7]; анларны татлығ уйқуларындин уйғатмақны рәва көрмәдим [293.10]; татлығ уйқусыны әзингә харам қылып [286.15; 313.10]; йызығы татлығ [439.10]. Мисаллардан күренгәнчә, *татлыг* сыйфаты туры һәм күчерелмә мәгънәләрдә кулланылган.

«Хөсрәү вә Ширин»дә: айур Ширин ма бир татлығ бар әрди [40r]; сугүнчүң әвкәң ош болдын ма татлығ [43v] ~ саңа аш болсун ошбу татлы халва [146.11]; мунуң тег татлы шәкәр йери ағзым әрүр [38r] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки» әсәрендә «татлы» сыйфаты еш кулланылуы күзәтелә: татлы судан ничек ки сусаучы [70а.2]; йетсә татлы суға сусамыш ир [48а.13]; сөзи татлы йүзи қутлы үзе камил [44б.1]; татлы җан чықса [132 б.13] һ.б.

*Татлы* сүзенең синонимы борынгы төрки истәлекләрдә теркәлгән سوجوك – *сүчүг ~ сүчүк* сыйфаты текстларда шактый эзлекле очрый, туры һәм күчерелмә мәгънәләре бар. Мәсәлән, «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә: чәриг сувсап турур тәқый һич сүчүг сув қатымызда йоқ турур [148.17]; мәним қатымда үч күп сүчүг сув бар [149.1]; сувы сүчүг әрдби [135.4]; ғәсәлдин сүчүг турур [59.7, 62.7]; мөбәрәк қонуқ көрклүг йүзлүг сүчүг сөзлүг [22.15]; тилләрини шәкәрдин сүчүг қылғайлар [402.5]; «Хөсрәү вә Ширин»дә: сүчүк болмаз туз [12v]; сүчүк тил бирлә алдамақ тиләрсән [55v.1] .

*Татлы* сүзенең синонимы фарсы алынмасы شيرين – *ширин* сүзе «Гөлестан бит-төрки», «Мәхәббәтнамә», «Хөсрәү вә Ширин» текстларында теркәлгән: «Мәхәббәтнамә»дә: ширин дудағлы [308б.3]; сөзүң ширин, өзүң Хөсрәвдин әфзун [50.273]; шәхи ким қылды хосрәвларны ширин [62.30]; ширин сөзүңдә [55.347]; ширин сөзлиләр бар [57.366]; «Гөлестан бит-төрки»дә: биш алты күн кичәҗәк ол булур сүкәр бикин ширин [127а.7]; ихсан билән қыл һәмишә ағзын ширин [35а.5]; ширин қыл шах көзингә сөз җамалы [1а.12] һ.б.

اجيغ – *ачыг* ~ اجي – *ачы* сыйфаты текстларда туры мәгънәсендә сирәк очрады, күбрәк күчерелмә мәгънәсе теркәлгән. Мисаллар: НФ.: дәрйалар сувы ачығ булды [170.7] һ.б. Истәлекләрдә үткен, ачулы сүз

мәгънәсе еш очрый. Мисаллар. НФ.: ничә ким ачығ әрсә татлы табдың [170.7]; ХШ: сәниң ачығ сөзүң шәкәр сифатлығ [43v]; бир оғлы бар әрди ... ачы сөзлүк [108v]; Гб.: бир ничә сйз ачы тил билән сөзләди [29б.2]; аның ачығындин ичи йануп отрур иди [65а.7]; Мн: ачық сөзи Қырым шәхдыға охшар [307а.8] һ.б.

توزلوق – *тузлуқ* ~ توزلوغ – *тузлуғ*: ики түрлүк тузлуқ тәқый қылмады [НФ. 109.14]; тузлуғ аш [ХШ. 4v.7]; болур әсрүкләр нәчә билгә уссуз аңар аш анда нә тузлуғ нә тузсуз [ХШ. 102v.7]. Тузлуғ сыйфатының синонимы буларак шур фарсы алынмасы кулланыла: шур суны күреп йақын килмәс [Гб. 22а.10]; буғдай тәмәғ итмә шүрә йирдән [Гб. 86а.4]; шүрә йиргә икти [Гб. 160б.9];

«Җөмҗөмә солтан» һәм «Кисекбаш китабы» истәлекләрендә предметның тәмен белдергән сыйфатлар бөтенләй кулланылмаган.

Шәхеснең тышкы билгесен белдергән сыйфатлар. Әлеге төр сыйфатлар нигездә кешегә, төп геройларга бәйле кулланылган. Әсәрдә мәгънә бирелеше үзенчәлеге ягыннан әйберләрне, күренешләрне төрле яклап ачыклап килә торган сыйфатлар белән беррәттән, шәхесне сурәтләүдә охшату-чагыштыру алымына нигезләнгән тасвирый сыйфатламаларның булуын билгеләп үтәргә кирәк. Сүзтезмәләр рәвешендә киңәйтелеп бирелгән сыйфатламалар геройларның образын тасвирлауда файдаланылган, поэтик-стилистик үзенчәлекләр тудыруда аларның рольләре зур. Күркәмлекне, матурлыкны, кыяфәтне белдерү өчен гомумтөрки һәм гарәп-фарсы теленнән алынма сыйфатлар шактый мул теркәлгән. Мәсәлән, Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәреннән мисал: Абу Муғид әйди Мәккәдә бир пәйғәмбәр чыкты тип Мөхәммәд атлығ... Маңа ол кишиниң сыйфатыны йахшы бәйан қылғыл Әгәр барсам йаңылмағай мән әзгү биләйин тиди. Йигит турур мәхасини қара турур ачуқ йүзлүг турур авазында һәйбәт. Ингән узун боҙлуғ әрмәз ашақ боҙлуғ тәқый әрмәз орта боҙлуғ турур. Ачуқ қашлуғ турур. Ингән сәмүз тәқый әрмәз ингән тәқый аруқ әрмәз орта тәнлиг турур. Төлек турур үкүш хәрәкәтлиг әрмәс. Тишләри сәйрәк турур. Йүзи толун ай тәг қумыйур. Сөз сөзләсә ачуқ айра сөзләйүр булгашуқ сөзләмәс. Айасы киң турур. Көзи ашаққа үкүшрәк бақар йеркә бақар бир аз тәқый башыны қалдурур көккә бақар. Мәхасини куртығ турур урта мәхасинлиг турур узун тәқый әрмәз ... [НФ. 23.3-9].

Алтын Урда чорында язылган әдәби әсәрләр телендә сыйфатларның бай синонимик оясын билгеләргә мөмкин.Текстларда борынгы төрки истәлекләрдә теркәлгән *көрүклүг*, гарәпчәдән *латиф*, *җамал*,

*сәхибҗамал*, *хөснүҗамал*, *җәмил*, *латиф*, *зариф,* фарсы теленнән кергән *зиба*, *һош* сыйфатлары йөзнең матурлыгын сурәтләү өчен кулланылган.

كوركلو – *көрүклү* ~ كوركلي – *көрекли* ~ كوركلوك – *көрүклүг* сыйфаты йөзне сурәтләүдә күпчелекне тәшкил итә. «Нәһҗел-фәрадис»тә: كوركوك – *көрүклүг* варианты 30 мәртәбә, ә كوركلو – *көрүклү* исә бер мәртәбә кабатлана, а) нигездә, кешегә бәйле рәвештә; ә) төрле күренешләргә бәйле кулланылган:

а) йана бир җәрийә көрүр мән бәғәйәт көрүклүк [65.9]; көрклүг йүзлүг әӡгү қылықлығ йигит оғлыңны боғузламақ [213.15]; қайу йердә көрклүг хатунны ишитир болса ол хатунны золм бирлә алур әрди [218.11];

ә) көрүклүг дарахатлары бар [64.14]; көрүклүг көшек көрдүм [65.4]; бир көшек көрдүм ғәйәт көрүклүг тәқый йүксәк [166.2]; көрклүг тонларыны кәӡәр әрди [207.3].

«Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә كوركوك – *көрүклүг* варианты өч мәртәбә, ә كوركلو – *көрүкли* ике мәртәбә кабатлана: Чин ичрә көркли йүзлүг [74 v]; көркли көзгә ай йүзи бирүр нур [12v], йигитләр көрклүси [51 r] тәлим әмгәнди қылды көрүкли сурәт [65r]; көрклүг қыз [82r] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки» әсәрендә: халык сөйләм теленә якын كوركلي (12 мәртәбә) һәм كوركلو (7 мәртәбә) кабатлана. Мисаллар: назым итеп көркли доғалар [7а.11]; көркли бустан бағышлады [69б.8] һ.б.

*Көрклүк* сүзе белән синонимик гарәп алынмалары әсәрләр телендә бертигез санда кулланылганнар. Гарәп алынмаларыннан جمال – *җамал*, *җәмил*, *латиф*, *зариф* сыйфатлары теркәлгән. «Нәһҗел-фәрадис»та: бу иқлимләрдә аның тәг җамаллығ ким әрсә хәбәр бәрмәс [180.3]; әй көрклүг җамаллығ [320.10]; Йосыф пәйғәмбәрне көрди инкән җамаллығ йүзи толган ай мәңизлик [352.6]; ғәрәб илләриндә аның тәг сәхибҗамал йоқ әрмиш [180.7]; җәмил турур, җәмалны сәвәр [371.8; 372.3]; йылан сурәти җөмлә җанварлар суратыдин латифрақәрди [280.9]; йәнә бир көшк көрдүм ғәйәт көрклүг зариф [165.17] һ.б; «Гөлестан бит.төрки»: көп малдан көркли җамал йахшырақ [98а.4]; оғлыны көрдүм ғәйәт җамал кәмал ичиндә [15а.11.12]; «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә: көрүп Шавур Шириннең күн җамалын [93v] һ.б.

Истәлекләр телендә ямьсез мәгънәсендә *көрксүз*, *җамалсыз*, *зишт* сүзләре очрый: Лабуза инкән зишт, бәмаза җамалсыз турур [НФ. 337.11]; йүзи көрксүз болғай бимаза сурәтлиг болғай [НФ. 399.6]; бир фақих ирниң инкән күрксиз қызы бар [Гб. 79]; зишт хат турур [Гб. 95] һ.б.

Геройларының кыяфәтен тасвирлау өчен, «Гөлестан бит-төрки» , «Хөсрәү вә Ширин» әсәрләрендә язучылар киңәйтелгән сыйфатламалардан файдаланган. Әлеге төр сыйфатламалар, нигездә, кешегә бәйле рәвештә кулланылганнар һәм күбесенчә тезмә формада киләләр. Мәсәлән, «Гөлестан бит-төрки» әсәреннән: бойу сәрви үә җамалы толун ай [15а.13]; бир қәмәр йүзли үни өздин хариф [61б.4], узун бойлы қәмәр йүзли киек көзли қырнақ бирип иди [70а.5] һ.б. Текстта кешенең тәнен, буй-сынын сурәтләгән сыйфатламалар да кулланылган: аның бигин қатты йүзли йумшақ тәнли мәхбүбтән вәфа килер [127б.4].

«Җөмҗөмә солтан» дастанында сыйфатның бу төркемчәсенә караган сүзләр күчерелмә мәгънә белдереп киләләр: чықты җаны, қалуп қоруғ гәүдә буш [163.27]; чөн төкәтте ул қоруғ баш сүзене [161.19]; андин әйде ул йәнә кем қоруғ баш [161.31]; әйде: қоруғ баш, и йәнә сүзләгел [165.18]; әйде тыйса и қоруғ адәм башы [159.11].

Предметның характерын, эчке билгеләрен белдергән сыйфатлар. Урта гасыр әдәбиятында язучының матурлык гармониясен күзаллавы шәхеснең сыйфатлары белән бәйләп карала. Сыйфат сүз төркеме эчке һәм тышкы гармониягә ирешкән кешенең рухи дөньясын сурәтләүдә зур роль уйный. Шунлыктан әдәби әсәрләр телендә кешенең характерын билгели торган лексик берәмлекләр күпчелекне тәшкил итәләр. Төрки чыгышлы сүзләрдән,اذكو – әҙгү, ايكو – әйгү, كوني – күни, قوتلو – қутлу, قوتلوغ– қутлуғ, جن – чын, الجاق – алчақ, يتيز – йәтиз, يوز – йавуз, يمن ~ يمان – йаман, اوسال – осал, алынмалар: عزيز – ғәзиз, صليح – салих, فرزانه – фәрзәнә, فانى – фани, باقى – бақи, خوار – хор, ظالم – залим һ.б.

Насретдин Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия» әсәрендә шәхеснең сыйфатлары белән бәйле сыйфатлардан төрки чыгышлы اذكو – әҙгү, كوني – көни, كونينج – көнинч, يلغان – йалган, يمان – йаман, гарәп-фарсы алынмаларыннан: حليل – хәлил, مهربن – миһербан, محبوب – мәхбүб, لايق –алайық, خوار – хор, ظالم – залим, رسوا – рәсвә берәмлекләре теркәлгән. Мисаллар:اذكو – әҙгү Салих қобсун [А519.1], мунда әҙгү атыңны әшитиб кәлдим [412]; сөзүң көни әрсә бизгә бир борһан күркүзгил [А12.16], сөзи көни болса биздин бурун өлмиш болғай [А15.19]; раст йолдамән [Б499] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, *әзгү, көни, раст* сыйфатлары синоним булып тора. Әсәрдә уңай сыйфатлар көнинч, лайық сыйфатлары аша белдерелгән: Алла Тәғәлә икимиздин көнинчрәк [Б182]; лайык хатун табылмады [ББ54] һ.б.

*Ғәзиз, миһербан* лексемалары кешенең характерын билгели торган сүзләр арасында актив кулланылышка ия: бир ғәзиз достум бар

[А510.5], мунуӊ тик ғәзиз башчыны пәйғамбәрликқә қабул қылмадылар [А13.15]; Иҙи миһербан турур [Б47]; Йәһүдә барчадин миһербан әрдиӊ [Б140] һ.б.

Тискәре сыйфатларны белдерү өчен *йаман*, *йавуз*, *залим* сүзләре кулланылган: қутғаргыл мәни бу залим халықдин [Б114]; әки әр йавуз [А14]; бу Ирмәлә йанлығзалим хатун болмады имишләр [Б363]; бу нәфс йаман ишгә башлаған турур [Б174] һ.б.

«Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә كوني – *көни* ~ اذكو – *әҙгү* ~ ارغ – *арыг* ~ صليح – *салих* ~ والي – *вәли* ~ حق – *хак* ~ خاليص – *халис* лексемалары бер синонимик оя тәшкил итәләр. *Әҙгү* бу төркем эчендә иӊ актив кулланылган сүз, текстта 67 мәртәбә кабатланган, гарәп алынмалары чагыштырмача сирәк файдаланылган: көни мүсүлман хәлендә [345.5]; хақ пәйғәмбәр турурсән көни дин бирлә кәлип турурсән [165.15]; көни йолдин азмагайсыз [168.15]; сәниӊ әҙгү ғәдәтләриӊ бар [8.10]; һошлуқ болсун әҙгү оғулға пәйғамбәр оғулға [53.12]; бу рай әҙгү рай әрмәс [70.8]; әҙгү сауабларынга йалғандурса [98.2]; әҙгү җәза бирсүн [101.12]; ол әҙгү ғәмәлләриӊә хәйир җәза бирсүн [439.16]; сизләр инкән әҙгү тәқи дүрүст йундуӊуз [172.3]; арығ: йер йүзиндә мүтәбәррик арығ хүрмәтлиг еү болса [НФ. 38.2]; хақ сөз тип бәлмиш [НФ. 226.17]; хақ пәйғәмбәр турур [НФ. 81.1, 111.15; 120.10; 143.15; 228.7]; Бәнү Исраил ичиндә бир салих кимәрсә бар әрди [НФ. 341.5]; ол вәли қуллар ғасилардан мәғсийат көрмиш [НФ. 306.5]; Хақ тәғәләниӊ вәлиләридин әрмиш [НФ. 375.13]; халис Тәӊри үчүн қылсаӊ [403.7] һ.б.

Фарсы алынмасы پاك – *пакь* һәр очракта төрки ارغ – *арыг* сүзе белән синоним буларак кулланылган: иманларыны золум бирлә қарыштырмадулар арығ чықтылар [НФ. 55.4]; кәрәкмәз сыйфатлардин арығ пак турур [НФ. 78.16]; Мәдинә шәһри хабис тәқый йаман кишиләрни өзидин кәтәрүр арығ пакларны тутар [НФ. 20.5].

ادكو – *әдгү* ~ *ару* ~ *арыг* ~ *вәли* ~ *пак*~ *сафи* сыйфатлары «Хөсрәү вә Ширин» текстында кулланылган. Гомумтөрки *әдгү* лексемасы еш очрый, 43 мәртәбә кабатлана, *арыг* лексемасы 17 мәртәбә төрле мәгънәләрдә теркәлгән: қамуғ елләргә әдгү аты чықты [46v.10]; нә әдгү нә йаман ким халқ [4r]; көӊүлләрне йарутты әдгү аты [4v]; әдгү аты ғәләмгә мәшһүр [6v]; вәли йарсызлықымдин рәнҗим артты [46v]; арығ көӊил [80v]; пак җан [4]; мүнәззәһ пак заты [114r] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки» әсәрендә кешенеӊ характер билгеләрен ачыклауда шагыйрь *йахшы, әйгү, йаман* антоним сыйфатлардан уңышлы файдаланган: йахшы қылыч булурму һәргиз йаман тимүрдин

[15а.6]; йахшы ир ивдәши йаман болса чәвер ичиндә [68б.5]; сән әйгү бол йаман дисин халаик йаман болуп сәңа йахшы дигинчә [62б.12] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки» әсәрендә изге, туры сүзле кеше төшенчәсе гарәп теленнән кергән ابرر – әбрар, صفا – сафа, خالص – халис, صدق – сыйддик,شريف – шәриф, ولى – вәли, زاهد – аһид, پارسا – парса сүзләре аша бирелгән: әрдәм ийәси халис misккә охшар [170а]; әгәр ул хөкем қылычыны чәкесә нәби вә вәли башын ашага чикгәй [175а]; Шам заһидларында бир заһид ир тағ әтәгиндә ...ғибадәт қылыр ирди [69б]; олуғлардан бир кимәрсә бир парса иргә сорды [49а]; шәриф кишимән Хиҗаздан килирмән [42а]; Зәвзән шәһриниң бир мәликиниң бир хоҗасы бар иди кәримүн нәфс сахиби холқ һиммәтли көңүлли [35а.7,8] һ.б.

«Кисекбаш» әсәрендә *әдгу* сыйфаты гына кулланылган: сөзләкәйим бир хоп әдгү дастан [5]; Хақның әдгү санғына танладулар [260].

«Җөмҗөмә солтан» текстында яхшы, изге мәгънәсендә خير – *хәйир* сүзе теркәлгән: бар күчүң йиткәнчә хәйир итмәк кәрәк [32].

Язучылар еш кына текстта сыйфатларны антоним буларак кулланалар: сәхини йад итип даим үгәрләр бөхил атын ишиткәндә сүгәрләр [Гб. 94б]; ол йавуз ишни қылур болса бир йаман иш қыды тип битиң [НФ. 60.4]; йаман сөз әйтүр [НФ. 121.10]; йаман қул әрдим [НФ. 147. 9]; йаман көзлүг көзин күн бирлә үртәр [ХШ. 12v]; хақ ишиң тәқи ғақибаты заһир болған турур батил ишиң ғақибаты заһир болған турур [НФ. 34.16]; нә әдгү нә йаман ким халқ [ХШ. 4r] һ.б.

Алтын Урда чорында язылган әдәби әсәрләр телендә төрки-татар, гарәби һәм фарсы чыгышлы сыйфатлар зур урын алып тора.Бу сүз төркеменә караган сүзләр арасында борынгы төрки лексик берәмлекләр белән янәшә шул чордагы халык сөйләм теленә хас формаларның активлашуы күзәтелә, шулай ук гарәп-фарсы алынмаларыннан сүзләр еш очрый. Әдәби әсәрләр телендә кешенең характерын билгели торган лексик берәмлекләр күпчелекне тәшкил итәләр. Әсәрдә, мәгънә бирелеше үзенчәлеге ягыннан әйберләрне, күренешләрне төрле яклап ачыклап килә торган сыйфатлар белән беррәттән, шәхесне сурәтләүдә охшату-чагыштыру алымына нигезләнгән тасвирый сыйфатламаларның актив кулланылуын билгеләп үтәргә кирәк. Сүзтезмәләр рәвешендә киңәйтелеп бирелгән сыйфатламалар геройларның образын тасвирлауда файдаланылган, поэтик-стилистик үзенчәлекләр тудыруда аларның рольләре зур.

## 2.3. Рәвеш

Рәвеш – эш-хәлнең билгесен яки билгенең билгесен белдерә торган сүз төркеме. Алтын Урда чорында язылган әдәби истәлекләр телендә эшнең сыйфатын, күләм-чамасын, үтәлү рәвешен, ягъни эшнең нинди дә булса билгесен белдерә торган сүзләр – билге рәвешләре төркемчәсе еш очрый.

а) Эшне үтәлү рәвеше яки башка билгесе буенча характерлый торган рәвешләр эшнең сыйфатын белдерәләр һәм күбесенчә фигыльгә ияреп килсәләр, предметны да ачыклыйлар:

اقرو – *ақру* ~ اقرون – *ақрун:* йүрүйүр болса акру йүрүйүр еркән йетәр [НФ. 23.9]; қатығ сөзләмәк ғәдәт қылып турур мән һич ақру сөзләйү билмәзмән [НФ. 371.13] ~ ақрун бу әр қатунға келү башлады [НФ. 383.6];

*Арқун:* арқун йол тутуп барур [ХШ. 91r]; күйүрмән һәм сызар мән арқун арқун [ХШ. 78v]; *ақрун:* темүрни ақрун ақрун әгсә болур [ХШ. 44 r]; әгәр айса тутайн зулфин ақрун [ХШ. 58v] һ.б. Фарсы теленнән кергән اهسته әһәстә синонимы сирәк очрый: пәйғәмбәрниң кулагына әһәстә айғыл [НФ. 28.12]; тутты тәқый әһәстә индүрди [НФ. 356.7];

ترك – *тәрк:* арзумуз сәңа инкән қатығ болды бизгә тәрк қавушғыл [НФ. 153.1]; ол нимә тәрк биткәй көп турмас [Гб. 166а]; атам тәркрәк өлгәй [Г134б] һ.б.

انوق – *ануқ:* қачан ойансалар ануқ болайын [НФ. 293.11];

توز – *түз:* йитип бир түз йазықа көчәдиләр [ХШ. 21r]; әрди көңлүм тән мә җүфтсүз тәним көңлүм билә ош болды түб түз [ХШ. 40r];

برك – *бәрк* : бәрк тутмыш әрди ғишық әтәгин [18 v]; атыны бир йығачқа бәрк бағлап [ХШ. 22r];ол эвнүң түнлүкини тәқый қапуғыны бәрк қылсақ [НФ. 19.12]; хисары бәрк әрди [НФ. 111.9] һ.б.

ياالينك – *йалың*: бәғзеләри йалың чықтылар [НФ. 80.2]; йалың қызмыш ташлар үзә сүрәр әрди [НФ. 96.15]; гизәр йалың баш аҙақ йүгрү түн күн [ХШ. 62v] һ.б.

محكم – *мүхкәм* (фарсы) «нык, көчле»: биз қапуғны мүхкәм сақладық [НФ. 136.6]; ғәләмни йердә мүхкәм тикти [НФ. 139.14]; қапуғларны мүхкәм бағладым [НФ. 268.12]; йана қаҙғу йақасын тутты мүхкәм [ХШ. 51r] һ.б.

تمام – *тәмам* [гәрәп]: чәрик әхвәлини тәмам айды әрди [НФ. 43.5]; Мүлҗәм эвкә кирсә тәқый тәмам мине көрсә [НФ. 151.16]; ол шәриф қасыйдәни тәмам оқуды исә [Гб. 42а]; лутф душманга көргүзүр болсаң

достлуқ шартын ол тәмам қылур [Гб. 15б]; тәмам биш йашқа йитти [ХШ. 8v].

Эш-хәлне күләм-чама ягыннан ачыклый торган рәвешләр. Истәлекләр телендә гомумтөрки сүзләрдән: *тәлим, үкүш, чук, күп, артук, тәмам*, гарәп алынмаларыннан *тәхкыйк* лексемасы теркәлгән: تليم – *тәлим* ~ اوكمش – *үкүш* ~ كوب – *көп* сүзләрен синонимнар буларак куллана. Ясалышы ягыннан алар тамыр сүзләр. «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә борынгы төрки اكوش – *үкүш* (340 очрак), تاليم – *тәлим* (4 мәртәбә), جوق – *чук* (тапкыр), *күп* (5) сүзләренең саклануы традицион лексиканың әле шактый эзлекле саклануы турында сөйли. Әлеге нәтиҗәләр статистик исәпләүләргә, сүзләрнең җөмләдәге синтаксик функцияләрен тикшерүгә нигезләнеп ясалды. Чагыштырыгыз: борынгы төрки текстларда ук теркәлгән تاليم – *тәлим* сүзе текстта барлыгы 26 тапкыр очрый, шулардан 16 очракта исемне ачыклап, предметның билгесен белдереп килсә, бары 10 мисалда процессның билгесен белдереп килгән. Мисаллар:

اوكمش – *үкүш*: үкүш зәхмәт тәгүрмиш [6.1; 9.3; 13.11]; үкүш ғилем билүр [8.14];үкүш васыйатлар қылур [15.5]; халаиқ үкүш турур [31.8]; үкүш қаҙғурды [НФ. 78.6]; үкүш йығладылар [96.3] һ.б.;

تليم – *тәлим*: бақар төрт йанында ағыр ишләр үкүш әмгәкләр тәлим тәғәт вә ғибәдәт бирлә қапшанмыш [НФ. 61.9]; икәгү үкүш йығладылар тәқый тәлим зарилық қылдылар [НФ. 282.5]. Текстта һәр очракта тәлим рәвеш сүз төркеме үкүш сүзе белән синоним буларак кулланылган.

كوب – *көп*: үкүш сөкти көп җәфалар қылды [НФ. 11.13]; хисабсыз көп чәрик қылды [ХШ. 222]; көңүл бахрында көп гәүһәрләриң бар [Мн. 292а] һ.б.

از – *аз*: өзләримизни нәчә аз охшатсак [128.14]; тәғәмни аз йигил тәқый аз уҙығыл [НФ. 266.8,17]; көп тәғәт вә ғибадәт қылмадым тип қаҙғурмағыл нәчә аз тәғәт қылсаң [НФ. 408.7]; ол йирдә сув аз ирди [43.16] һ.б.

Микъдар рәвешләре. Алар процессның яки билгенең дәрәҗәсен, күләм-чамасын белдерәләр. Мондый рәвешләр фигыльгә, сыйфатка һәм башка бер рәвешкә ияреп киләләр.

ارتوقق – *артуқ* сүзе «күп, кыйммәтле» мәгънәләрендә кулланылган: артуқ зәхмәт тәгрү башладылар [НФ. 13.10; 14.1; 161.9]; артуқ рәхмәт қылған сән турурсән [НФ. 333.6]; қул қаравашларны артуқ әмгәтмәң [НФ. 87.2]; Абу Бәкерне өзгәләрдин артуқ тутар [НФ. 94.1].

بوتون – *бүтүн*: бу сүтни ичиң бақалың бағарсуқларыңыз бүтүнмү турур [НФ.118.12];

دایم – *даим* (фарсы алынмасы): даим түшәр мәшәкәтниң қатына [Гб. 28а]; илиң бар болсун даим [ХШ. 61r]; үч нәмә даим қалмас [Гб. 161а] һ.б. ;

جاودان – *җәвидан* (фарсы): атың қалғай җәханда җәвидан [Г130а]; җәһан қалмас кишигә җәвидана [Мн. 295а];

اینکان – *инкән* берәмлеге бик, күп мәгънәләрендә теркәлгән НФ. әсәрендә актив кулланылган, 210 мәртәбә теркәлгән: аның савабы инкән өкүш болур [НФ. 408.8]; Ғәли аз нәрсәләр бирмиш [НФ. 160.5] һ.б.

Фарсы теленнән кергән синонимы زیاده – *зийадә* (фарсы) тикшерелә торган чыганакларда сирәк кулланылган: Йусуфны өзгә оғланларыдин зиадә сәвәр әрди [НФ. 353.2]; зийадә бәхшиш қылың [НФ. 49.10];

تمام – *тәмам* (гарәп): ол чәриг әхвәлини тәмам әйди [НФ. 43.6];

اوزاق – *узақ* сүзе 6 мәртәбә умыныч сүзен ачыклап килгән, бары бер мисалда фигыль сүз төркемен. Мисаллар: узақ умыныч бирлә иртәләдим [НФ. 147.4; 433.3; 435.3,4; 433.14; 435.2]; бу сөкәлликиң инкән узақ болды [НФ. 221.4] һ.б.

Вакыт рәвешләре. اشنو – *ашну*: пәйғәмбәр туғмаздин ашну вафат болуп турур әрди [НФ. 4.13]; көрүкли көрмәдүк тәмишләр ашну [ХШ. 111r]; ашуну җиһандин ашну миң йыл қылды халиқ [Мн. 170б] һ.б.;

ارته – *әртә:* буйур Шәбдизни әртә кәлтүрсүнләр [ХШ. 78r]; қоптылар әртә кәлдиләр [НФ. 42.2]; әртә кәчә һиҗабсуз хәлифә хәзрәтингә кирүр әрмиш [НФ. 302.15]; әртәси қәйлүлә вақты болды [НФ. 283.4] һ.б.

بکون ~ بوکون – *бүгүн:* бүгүн әҗәлим йитгәй [НФ. 167.2]; анамыз бизгә бүгүн һичнәрсә бәрмәди [НФ. 173.1]; бүгәндин соҗ йүз йигирми йыл йашағыл [Мн. 163] һ.б.

Борынгы төрки ташъязмаларында теркәлгән یارین – *йарын* берәмлеге иртәгә мәгънәсендә «Нәһҗел-фәрадис», «Гөлестан бит-төрки» текстларында очрый: бүгүн Мөхәммәд Мәккәни алды йарын бизләргә кәлгәй [НФ. 69.3]; бүгүн йарын Шам чәриги кәлгәй [НФ. 184.4]; йарын икәгү өлгәйсиз [НФ. 280.15]; ол кишини отқа йақарлар йарын [Гб. 131б];

بیلدر – *былдыр:* былдыр бу Мәдәйин шәһрингә кәлмиш әрдим [НФ. 309.11];

بورون – *бурун:* бурун қәрендәшимиз оғлы Абу Талибдин қорқар әрдиләр [НФ. 13.10]; бурун кирди бақты [НФ. 21.3]; [Гб. 72а]; бурун он дидим он бир болды [Мн. 309а]; буруңдин сонқа тәгрү көргәнин ол [ХШ. 28v] һ.б.

Урын рәвешләре процессның үтәлү урынын белдерәләр.

يراق – *йырақ*: анының қатындин йырақ киттим [НФ. 137.6]; сиз җүмлә йырақ туруң [НФ. 149.12]; мунча йырақ йирдин килип муңа зийарат қылдыңыз [НФ. 155.8]; көңли Хақ тәғәлә хәзрәтиндин йырақ түшти [НФ. 245.10]; ол йердин кәчсә йырақ барса [НФ. 260.2]; йырақ болсун җамалыңдин йавуз көз [Мн. 296б]; көрәр болса йырақдин аны арслан [ХШ. 19r] һ.б.

توبان – *түбән*: сизләр мунуң үзә түбән түшәр әрдиңиз [НФ. 399.8]; өчәккә минип төшәриндә тәқый түбән йықылды [НФ. 365.6]; Бабил қуҙуғында түбән астылар [НФ. 367.11.12] һ.б.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Алтын Урда чоры язма истәлекләрендә эш-хәлне төрле яклап ачыклап килгән рәвешләрнең эшнең сыйфатын, күләм-чамасын, үтәлү рәвешен, вакытын, урынын белдергән төркемчәсе кулланылыш тапкан. Әдәби әсәрләр телендә, борынгы төрки чордан килгән архаик лексика белән беррәттән, гарәп-фарсы алынмалары зур урын алып тора. Рәвеш сүз төркеменә кертеп каралган сүзләр синтаксик яктан киң функциягә ия, алар күбрәк фигыльне һәм исемне ачыклыйлар, ягъни борынгы әдәби телдән килә торган сыйфат, рәвеш сүз төркемнәренең дифференцияләшеп бетмәве саклана.

## 2.4. Сан

Алтын Урда чорында язылган әсәрләр телендә саннарны белдергән сүзләрнең составы, борынгы төрки чордагы саннар кебек үк, унарлы системада төзелгән. Тамыр саннар күп түгел, алар, предметларның микъдарын белдереп, санау өчен кулланыла.

Истәлекләр телендә саннарны белдергән сүзләрнең зур өлешен берәмлекләрне белдергән сүзләр тәшкил итә: بير, بر – бир, ايكي – ики, اوج – үч, تورت – төрт, بيش – биш, التي – алты, يتي – йети, سكيز – сәкиз, توقوز, تقوز – токуз саннары, дистәләрне белдергән اون – он, يكيرمي – йигирми, اوتوز – отуз, قرق – кырык, ايليك – илиг, التميش – алтмыш, ييتمي – йитмиш, ساكسان – сәксән, تقسان – туксан саннары очрый. Саннарның калган өлешен шул ук саннардан ясалган кушма һәм тезмә саннар тәшкил итә. Саннарның күпчелеге гомумтөрки сүзләр, алынмалар сирәк теркәлгән. Саннар саналмышка бәйләнгән хәлдә һәм саналмышсыз да кулланылган. Истәлекләр телендә алар, үзләренең семантик табигатеннән тыш, стилистик роль уйный. Мәгънәләре һәм грамматик билгеләре ягыннан әдәби әсәрләрдә саннарның биш төркемчәсе дә урын алган.

Рабгузиның «Кыйсасел-әнбия» әсәрендә 169 сан берәмлеге теркәлгән, саннарның кулланылуында традицион әдәби телдән килә торган борынгы төрки телгә хас формаларны билгеләргә мөмкин.

*Микъдар саннары*:بير – бир [А502.4], اكي – еки [А508.8], اوج – үч [А512.11], تورت – төрт [А7.4], بش – беш [А515.11], يتي – йети [А516.12], توقوز – тоқуз [А509.1], اون – он [А509.1], يكيرمي – йигирми [А14.13], اوتوز – отуз [А517.7], قرق – қырық [А8.15, А19.11], اليك– әлиг, يتمش – йетмиш [А7.17], مينك – миң [А511.7].

Микъдар саннары, предметларның исәбен белдереп, исемне ачыклап киләләр: йүз миң йигирми төрт миң пәйғамбәрләрни дақы сени йаратмағай ердим қамуғыны аның сүкүклүки үчүн йаратдым [А518.4.5]; бу бутқа төрт йүз қылдурды [А7.4].

Фарсы теленнән кергән هزار – *һазар* сүзе мең саны исәбен белдерә: әй ахмак тәңри йарлығы бирлә һазар җан фида болсун [А511.13]. مينك – *миң* саны текстта төрле мәгънәләрдә кулланыла, арттыру алымы буларак отышлы файдаланыла: миң йыл тады йығачында қондум [А9.16]; көз йумуб ачғынча үч миң йыллық сыратдын кичәр [А516.10].

بير – *бир* саны семантикасының киңлеге, кулланылыш ешлыгы белән саннар арасында аерылып тора, туры, үз мәгънәсендә кулланыла, билгесезлек төсмерен белдереп, билгесезлек артикле вазифасын башкара, кушма рәвеш ясауда катнаша: бир оч топрағ келтүргил [А11.4]; тигмә дәрвәзәдин йана бир дәрвәзәгә бир йығачлық йер ерди [А18.16]; бир әбүшкә келиб мени фәсүс тутар [А511.15]; Җабраилни көрди бир қуч алыб келүр [А513.24]; бир бут қылдылар қыры узунлуғы секиз қарыш [А.2] Самуд бир күн ол көлдә бир ташдин үн ешитди [А13.4]: екиләси зәбих турурлар бир йолы Исмәғил ерди бир йолы Исхақ [А508.5] һ.б.

Текстларда вакыт исәбен белдергәндә *йыл*, *ай*, *күн*, *сағәт* һ.б. саналмышлар актив кулланылган: он секиз йыл тирилди [А19.10]; йети күндин суң Сара суңукында Исхақ билкүрди [А517.23] һ.б.

*Тәртип саннары.* Тәртип саны саналмыш әйбернең сан ягыннан тәртибен белдерә. «Кыйсасел-әнбия» әсәрендә эзлекле рәвештә сан нигезенә *-нч, -нчы/-нчи* кушымчалары ялгана. Чагыштыр: екинчи [А515.20], үчүнчи [А513.1], төртүнч [А515.3] – төртүнчи [А515.21], онунч [А509.5]. Беренче мәгънәсе гарәп алынмасы «әүwәл» сүзе белән белдерелгән: әүүәлги күн йүзләригиз сарғарғай [А15.15].

Бүлем саны *-ар/-әр* кушымчалары ялганып ясалган: тигмә қабиләниң бирәр маликләри бар ерди [А6.19]; бу тәрк бирлә онар онар олтуруң [А509.14].

*Җыю саннары.* Әсәр телендә җыю санының борынгы төрки әдәби тел традициясенә хас *-әгү* формасы гына теркәлгән, сирәк очракларда *-ләси* кушымчасы кулланылыш таба: екәгү кеңәш қылдылар Йусуфға түшүмизни айталың [А509.7]; екәгү оруштылар ол халдә Муса келди [А18.13]; үңүр ачылды екәгү кирдиләр [А10.3]; бу екәгүдин тәлим оғланлар болды [А5.17]; емишләр екиләси зәбих турур [А508.4].

Алтын Урда чоры язма истәлекләре телендә сан сүз төркеме еш теркәлгән, биш лексик-грамматик төркемчәсе урын алган.

Микъдар саннарының график чагылышы түбәндәгечә:بير – бир [123.4],اكي – әки [18, 118, 143] ايكي – ике [231.1] ~ ايكا – икә [332.16], اوج – үч [21.47],تورت – төрт [15.8],بش – бәш [254.7] ~بيش – биш [261.4], التي – алты [267.4], يتي – йәти [269.5],سكيز – сәкиз [207.11],توقوز – тоқуз [286.12], اون – он [246.7], يكيرمي – йәгирми [242.1],اوتوز – отуз [261.4], قرق – қырық [236.15], اليك – әлиг [250.17], التمش – алтмыш [101.8], يتمش – йәтмиш [302.13], سكسن – сәксән [258.7], يوز – йүз [254.3], үч йүз, مينك – миң [171], үч миң, үч йүз миң, اليك مينك– әлиг миң [193.3] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, саннарның төп лексик фонды гомумтөрки чыгышлы. Саннар, предметларның данә исәбен белдергән хәлдә, исемне ачыклап киләләр, сирәгрәк фигыльне дә ачыклыйлар: он алтун бирүрләр [246.7]; бир абушқа бар әрди Дурайыр атлығ олуғ йашлығ йүз йигирме йәшәйүр әрди [69.15].

Микъдар саннары түбәндәге нумератив сүзләр белән кулланылган: баш: алты баш қул қарвашлар ким кәферләр илкиндә әрди [97.14]; Әбубәкр бу йети баш кишиләрне алып әвенгә кәлде» [257.15]; аршун: тәрисенең қалынлықы қырық ике аршун [66.16], батман : төрт батман арпа [27] һ.б.

Вакланмалы саннар ясалышы буенча тезмә саннар кебек, беренче сан икенче санга урын-вакыт формасы аша бәйләнә: имам Шәфиғи түннүң үчтә биринкә тәқый намаз қылды [198.14]; түннүң үч үлүштә бири кичәр булса [322.9].

*Йарым*, *бучуқ* сүзләре дә микъдар санына керә: йарымы йепәк торур тәқый йарымы йип торур [246.2, 97.12, 324.14, 245.16, 324.14 һ.б.]; бучуқ батман қызыл алтын биргел [97.8, 104.3, 176.9, 321.3, 322.11, 344.5 һ.б.].

*Тәртип саннары.* Тәртип саны саналмыш әйбернең сан ягыннан тәртибен белдерә. «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә эзлекле рәвештә сан нигезенә *-нч/-нчы/-нче/-унч* кушымчалары ялгана, борынгы төрки телгә хас *-нч* күрсәткече норма булып тора. Чагыштыр: التنج – алтынч [36.2, 55.6, 168.4, 273.13, 282.15,390.8, 443.15]; ~ التنجي – алтынчы [240.16];

بشنج – бәшинч [55.14, 27.5,156.13, 269.11, 380.16]; ~ بشنجي – бешинчи [234.10]; تورتنج – төртинч [2.15, 18.13, 30.14, 54.10, 213.4, 247.6, 259.14, 334.13, 348.5, 371.2, 410.16] һ.б.

Беренче мәгънәсе гарәп алынмасы («әүүәл» һәм гомумтөрки «илк» сүзләре белән белдерелгән): әүүәл уақтын аңлара сабыр қылмақ күчәй болғай [304.15]; илк қат күккә кирдүк [28.10].

Саналмышлары төшеп калганда, тәртип саннары исемләшеп киләләр: төртүнчисидә йәнә қурыды [30]; үчүнчүси халаиқа йумшақ сүзләмәк [254.16].

Бүлем саны *-ар/-әр, -шар/-шәр* аффикслары ярдәмендә ясала: хатунлардин икишәр тәқый үчәр җефтләнең тәқый түртәр җефтләнең [193.1]; йетешәр ултурсунлар [192].

*-н* кушымчалы сан, кабатлап әйткәндә, бүлү төсмерләрен белдерә: бирин-бирин кәлеп бәйат бирделәр [94.12].

*Җыю саннары.* Әсәр телендә җыю санының борынгы төрки әдәби тел традициясенә хас *-әгү* формасы актив кулланыла: биз үчәгү бардук [53.5]; бу түртәгү бойға йеттиләр [337] һ.б. Әсәр телендә ايكاكو – *икәгү* җыю саны 69 мәртәбә теркәлгән: 20.4, 50.13, 103.4, 107.2. 140.3, 170.16 һ.б.; *үчәгү* – 6 мәртәбә: 39.13, 53.5, 66.3, 218.10, 292.11, 135.9 һ.б.

Исемләшеп килгән тәртип саннары җыйнап әйтүне белдерә, бер җөмлә эчендә *-әгү* формасы белән вариатив кулланылыш очраклары күзәтелә: ике күшк күрдүм икесе йәнәшү турур [179.8]; биш буғдай үзде тәқый икесене үзе йәде [281.6]; бу икисини сәүгүл тәқый бу икәгүне мунлар уруғыны... сақлағыл [160.1].

Җыю саннары исемләшеп киләләр һәм исемнәр кебек төрләнәләр: кәферләр бирлә урушмақа чықты икәгүсе [299.10], икәгүгә буйурғыл [282.5]; пәйғамбәр тәқый Фатыйма икәгүн әйтерләр [153.17] һ.б.

Тестта сирәк кумулятив *-әгүлүк* формасы очрый: Ибраһим Сара тәқый Лот пәйамбар үчәгүлүк Дамашқ илидин чықтылар [218-10].

«Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә саннарның төзелешендә, формасында традицион әдәби тел белән уртаклык аеруча зур.

Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә саннарның кулланылышы.

*Микъдар саннары.* Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә микъдар саннары – иң еш кулланылган сан төркемчәсе.

بير – *бир* саны семантикасының киңлеге, кулланылыш ешлыгы белән саннар арасында аерылып тора:

1) *бир* саны предметның бер генә данәдә булуын белдерә, һәм бу – аның төп парадигматик мәгънәсе. Мәсәлән: бир авуч тобрақ-

дын йаратты мана [117r]; йетиб кирүр ол ингә бир йылыан тег [14r] һ.б.

*Бир* саны кадерле, бердәнбер мәгънәсенә ишарә итә: ерүр бир тәңри йары ортақы йоқ һәм андин өзгә бир тәңри тәқи йоқ [114 v], нә йүз сөзләгү кәрәк бир сөзни ахыр билигликкә йетәр сөз кәртүси тир [87 r] һ.б.

*Бир* саны вакыт яки ара белдергән сүзләр белән актив кулланыла: Бир ай йүриди тынмадин тутуп йол Муһин Бану әлингә әмгәнип ол [14v]; қылалың бир кечә тәрк ошбу уйқу [28r] һ.б.

*Бир* санының икенче мәгънәсе – билгесезлек төсмерен белдерү: көрәр бир йир һавасы табғи әфйун [26 r]; табуп чимгән рәйһанлы бир йир [37 v] һ.б.

Саналмашыннан башка килгәндә, сан исемләшә, әлеге күренеш «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә урын ала: бири бүлбүл мәңиз он йырла сайрар чичектег бири чимгән үзрә ойнар [15v], бири саруғ бири ал бири зәнги [14v] һ.б.

Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә ایکی – *ике* саны да күп теркәлгән, нигездә туры мәгънәдә кулланыла: ики түрлү кишигә хөкем етмәз [58v]; һәр ертә кечә күндә ики нәүбәт [7v], бар ерди падишаһның ики чадыр [94r]; нә дөнйа нә дин ики җиһансыз [66 v] һ.б.

Әлбәттә, әсәрнең нигезендә мәхәббәт, ике кеше арасындагы җылы хисләр – ике гашыйк, ике яр, ике җан. Шуңа күрә дә текстта *ике* санын белдергән лексик берәмлекнең еш кулланылуы табигый. Мисаллар: нитәк ким ғишқы арты ики йар шәшип җан дәфене бағ ичрә ойнар [37r]; ким әй Хақ лутуф қыл ол ики җанны [113r] һ.б.

Ике санының бер строфада кабатланып, бер саны белән каршы кую очраклары әсәрнең тәэсир көчен арттыра. Мәсәлән: йыпар тауық тау ики бойнында асылмыш күмүш нар ики төшингә тағылмыш [104r]; ики аучы килип бир ауда кирди замана ошбу йаңлығ ау қурды [33v]; ики зирәк ишиттим бир заманда [107v] һ.б. Саналмышы төшеп калган очраклар да әсәрдә еш урын ала: ким антег көрмәмиш ерди аҗун қылы вә тили икиси [95r].

*Ике* саны мәкальләр составында теркәлгән: ики хатун йарашмаз тейү һәр гез [54v]; узақдин битәррәк ики сөзлүг ерүрсән дәйимә һәм ики сөзлүг [90r] һ.б.

Әсәрдә اوچ – *үч* саны вакыт, озынлык чиген билгеләгән мисалларда теркәлгән: үч аршун дастарым бирлә узақ йол [55r]; түшүп тәхтендин үч күн йәш тутты [53r] һ.б.

تورت – *түрт* саны әсәр телендә дүрт якны, дөньяның дүрт өлешен белдерү өчен кулланылган. Мисаллар: аның төрт йаны чимкән ерди хүррәм [9v]; түшүб ғишрәт қылалуң теди бир дәм [13v]; ешиттим бар аймыш төрт билгә әүвәл [107 v] һ.б.

Вакланмалы сан составында кулланылуы да теркәлде: ерүр бу төртдә бири ол тири нең йәнә бу бир тири төртдә биринең [114v] һ.б.

*Биш* саны яшьне белдерә: тамәм биш йашқа йитти ерсә [8v].

التي – *алты* саны белән бер генә мисал кулланылган, шулай ук яшь аралыгын аңлата: қачан ким алты йашқа йитти ол шаһ [8v].

يتي – *йети* саны ислам динендә дә, христиан динендә дә уңышлы, бәхетле сан, бөтенлек, камиллек, символы булып тора: йити иқлим, йити қат йир, йити қат көк һ.б. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә җиде саны еш кулланыла: йити иқлим шаһның ол йадгәри йоқ ол дүнйада бир көрк ичрә бәри [18 r]; йүритүр йәти иқлим үзрә фәрман ғәләм йити фәләкдә тикмиш әйвән [19r] һ.б.

توقوز,تقوز – *тоқуз* (саны: тоқуз уақтында әлгә алса йашын [19r]; тоқуз йашында соң ойунны салды баһадурлық қылычын әлгә алды [9r] һ.б.

اون – *ун* (саны: йетиб он яшкә киш бағланды бәлгә [9r]; қари болғай йәш оғлан турса он күн [32v]; тең ермәз әлдә он бармақ бил аны [104v] һ.б.

*Онтөрт*, *онбиш* саннары вакытка бәйле, яшьне белдерү өчен кулланылганнар: тәмам ким ғөмри он төрт йәшкә йетти [9r]; йелип онтөрт түн күн йар тиләйү [22r]; үәли ғөмриндә онбәш йашар анчақ [19r] һ.б.

اوتوز – *отуз:* сүт еммәзмән бар ағзымда отуз тиш [90 r];

ييتميش – *йитмиш*: түкәл йитмиш асылзадә қатында [13r]; түкәл йетмиш пәри биргә йыйылды [21r]; йетмиш йети иқлим шаһы [31v].

يوز – *йүз* саны еш файдаланыла, туры мәгънәдән бигрәк, күплекне, гадәттән тыш арттыруны белдерә: әгәр қылсам йыпардин айға зәнҗир қылурмән йүз миң арсланны нәһҗир [35r]; йүз алтун ерди һәр күн тутсу харҗы [74r]; бирингә йүз җавабын ишиттим [72v].

Вакытны белдергән очракларда *йөз* саны гиперболик кулланыла: әгәр тобрақ үзрә йүз йыл сән отурсаң тапмағайсән аны бил сән [70v]; аныңтег йүз йыл издәсәң табулмаз қуруғ қәҙғу йимәкиң асғы болмаз [70v]; һәнүз йүз йар вә аның иши һәм ол [88r] һ.б.

*Йөз* саны «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә мәкальләрдә урын алган: өзүң йүз пәрә қыл гүлтег бу бағда [2r]; бәрүр бир лутуф бирлә җанны ол өң алур йүз қаһир бирлә ғақибат соң [113v] һ.б.

Түбәндәге юлларда хайваннарны рәнҗетмәскә куша, аеруча атның кыйммәтен күрсәтә: вәли атны хош асраң бермәңиз рәнҗ ким ол атның баһасы йүз түмән дәнҗ [25v].

مینك – *миң* саны текстта төрле мәгънәләрдә кулланыла, арттыру алымы буларак отышлы файдаланыла: өдүкдә тәқәти чын тәк бурунқыдин миң артуқ муштақ болды [47v]; айтты ким әгәр йел болсамыз биз йетәр йелдин миң артуқрағ ма Шәбдиз [21v];

Башка саннарның кулланылышын күзәтик:

*еллиг миң:* тамәм еллиг миң ер барча сағытлығ [45r];

*йүз миң:* тәгәр байлыққа йүз миң болса дәрвиш [19r]; мәним көңлүмни йүз миң пара қылды [40r]; ичиндә мунча йүз миң әдәми бар [114v].

Фарсы теленнән кергән هزار *һазар* сүзе мең саны исәбен белдерә: һәзар рәхмәт сәниң көңлүңгә кәлсин [97v].

تومن – *түмән:* түмән Хөсрәү қулуң болса йарар ерди [6r]; мәлик билмәзаны ким ошбу қызлар табунса қаршу турмазмиң түмән ер [35v]; бу бир йазуққа ғөзрүм миң түмән бар [99 v] һ.б.

*Тәртип саннары.* Тәртип саны санала торган предметның сан ягыннан тәртибен белдерә. Әсәрдә эзлекле рәвештә *-ынчы/-енче* тәртип саны кушымчасы урын ала, борынгы төрки әдәби телгә хас *-нч* чагыштырмача сирәк күзәтелә, бары гарәпчә «әүүәл» варианты кулланылган. Мисаллар: Хөсрәү вә Ширин хикәйәтинин әүүәли [8v]; фәләк хақ хүкмин әүүәлрәк йүритти [52v] һ.б.

*-ынчы:* икинчи ғишқы чақмақы чақылды Ширин көңли чырай йаңлығ йақылды [99v]; икинче Ғомәр ерди дин башлаған кәтирләр башыны кәсиб ташлаған [8v]; йегитләр һәм қариларны икинчи кетәр чимгән көрүп қаӡғу сақынчы [36v]; икинчи хәҗәтим сендин ерүр ол [94r]; йәнә сәксинчи күн әсрүк болуп шаһ [101r]; йәнә бәшинчи күн мәҗлис қуралым [53r]; үчүнчи күн хазинә қабғағын ачты [53r];

*-нч:* икинч ким кәстиләр атың аӡақы [11r]; икинч елгә алыпол тишәсини йәнә башлар узақы пишәсини [67r]; үчүнч Ғосман ерди увутлуғ ақы [5v]; бу төртнч Ғәли ол әрәнләр башы [5 v] һ.б.

Икинчи саны башка сүз төркемнәренә күчә: шаһ әндәмин йәнә қан бирлә йуды икинчи қанқа булашты вөҗүдү [113r] һ.б.

*Чама саннары.* Котбның «Хөсрәү вә Ширин» текстында чама саны, нигездә, үзара якын саннарны кабатлау юлы белән ясалган, бары 11 мәртәбә теркәлгән: бир ики һафта мән мунда болайын нитәк кичмиш аның һәлин биләйин [29v]; бу бәш он күн ичрә рәхим қыл маңа [117r]; бир ики һафта сахрада болурмән [22v]; тиләсә зәүк атын сүрмәккә нәгәһ

отуз қырқ мәйил тыңмаз ерди ол шаһ [75v]; бу ғөмри ким ерүр әллиг йә алтмыш [98r]; бәш алты кәфир көрсә бириндә ғилим [117r] һ.б.

*-ча* кушымчасы саналмышка ялганган очраклар сирәк: бир айча артуқ әксүк сабыр қылды [71v]. Чама мәгънәсен белдерү өчен, артык сүзе кулланыла: йүзүңнүң көркин анчақ өк мәңа сән не ким айсаң миң артуқ сән билүрсән [85v]; тег ол йергә төшәгү қалылардин не йүз ким бар иди айды бәш йүздин артуқ [101v].

*Җыю саннары.* Җыю саннары сан нигезенә *-ағу/-әгү* кушымчасы ялганып ясала: бу төртәгүдин өң мә йаранлары фида қылдылар хаққа тән җанлары [5v] һ.б.

*Микъдар саннар* предметларның сан буенча бергә җыйналуын белгертә ала: шаһ айды биз ики тоб ойналың қайумуз йахшы ойнар бир бақалың [36r]; биз ики бир көңүл болмушда кезин [75v]; бу төрткә авуны кәчрүр ерди Пәрвиз [105v] һ.б.

*Бүлем саннары.* Әсәрдә бер саны нигезендә ясалган бүлем саннары теркәлде: *-әр:* бирәр сақшап барур [39r]; *-ин:* тонуб кәҙдүрүп қаравашларда бирин [76v]; җиһатка алты көнләк ол кәҙүрди йана бир үзрә төрт гәүһәр өҙүрди бирингә бәрди бәхшиш ким йетүргәй бирин қушқанч қылды ким йетүргәй [2v] һ.б.

«Кисекбаш» әсәрендә саннарны белдерә торган сүзләрдән микъдар саннары урын алган, башка лексик-грамматик төркемчәләр аз кулланылган:

بیر – *бир* саны семантикасының киңлеге, кулланылыш ешлыгы белән саннар арасында аерылып тора, 22 мәртәбә теркәлгән. Предметның микъдарын белдереп килә: бир хикәйәт кәлди тилимкәр сөзләкәй [А13]; Ғәли бақты көрди бир темур қапуғ [А128]; Ғәли көрди йәнә бир улуғ сарай [А137]; бир халәлым бир хоп уғланум бар иди [А63]; сөзләкәйим бир хоп әгү дастан [А5] һ.б.

*Бир* санының икенче мәгънәсе – билгесезлек төсмерен белдерү: бир кесүк башдур һаман сөзләр тили [А28]; бир хатун олтурмыш ирди йүзи ай [А130]; көрдиләр ким бир кесүк адәм башын [А23]; нәгиһән бир сахарağа йетдиләр [А 100]; Ғәлини узаттылар бир мәнзилә [А85] һ.б.

Саналмашыннан башка килгәндә, сан исемләшә:

*бир:* һич мунуң тәк бири тағы йоқ турур [А8]; бу җиһанда қоймаин бириңизни [А186];

*ики:* ики көзи йәш ирүр [А26]; ол икиси мәңә мунис һәм йар иди [А64];

*үч:* үч йүз деүни өлтүрди ол күн Ғәли [А222]; үч хамлә қылды Ғәлигә өлмәди [А99];

*төрт:* ол дәү ойғанды та төрт йану бақар [А171]; Рәсүл алтурмыш ирди төрт йар илә [А19];

*беш:* беш намаз кылур Ғәли ақты билә [А94]; күндә бешимизни сойды йеди [А148];

*йети:* йети күн түн чүн булар киттиләр [А99]; йети түни һәм күни [А122];

*илли:* елли кезин бармыш ирдим мән хаҗа [А51];

*йүз:* келди беш йүз мүсүлман чешти илин [А227]; үч йүз девни өлтүрди ол күн Ғәли [А231] һ.б.;

*миң:* миң батман көрзиси бар өзи билә [А198]; ол дев әйтүр миң йәшәдим темәдим [А205] һ.б.

Тәртип саны ике мисалда теркәлгән: секзинчи күн аҙақы текти йерә [А133]; икиләнчи нағрә орды ол ғази [А169].

Күзәтүләрдән күренгәнчә, истәлекләр телендә чагылган саннар системасының төзелешендә традицион әдәби тел белән уртаклыклар күзәтелә. Саннарның күпчелеге гомумтөрки сүзләр, алынмалар сирәк теркәлгән. Саннар саналмышка бәйләнгән хәлдә һәм саналмышсыз да кулланылган. Истәлекләр телендә алар, үзләренең семантик табигатеннән тыш, стилистик роль уйный. Мәгънәләре һәм грамматик билгеләре ягыннан әдәби әсәрләрдә саннарның биш төркемчәсе дә урын алган. Саннарның кулланылышында традицион әдәби телдән килә торган борынгы төрки телгә хас формаларның, орфографиянең норма булып торуы күпсанлы мисаллар белән дәлилләнә.

## 2.5. Алмашлык

Борынгы сүз төркемнәренең берсе булган алмашлыкларның Алтын Урда чоры язма истәлекләре телендә дә күп төрле төркемчәләре гамәлдә йөри.

*Зат алмашлыклары.* Алтын Урда чоры язма истәлекләре телендә түбәндәге зат алмашлыклары теркәлгән:

| | | |
|---|---|---|
| I зат | мән ~ бән ~ мин | биз ~ бизләр |
| II зат | син ~ сән ~ сен | сиз ~ сизләр |
| III зат | ол | анлар ~ мунлар |

Зат алмашлыкларының кулланылышы шул чор әсәрләре өчен хас уртак үзенчәлекләргә ия. Чагыштыр:

Насретдин Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия» әсәрендә зат алмашлыкларының кулланылышы түбәндәгечә:

I зат: من – *мән*: мәңа хақрақ турур мән алурмын [А.10.9], мәниң боғузумны нәтәк кесәр [А513.5]; بيز биз: бизгә сүт берсүн биз ичәлиң [А13.2], биздин бурун өлмиш [А15.3].

بيز – *биз* алмашлыгы текстта еш очрый, меңнән артык мисал тупланды, төп мәгънәсендә кулланылган, стилистик максатларда сөйләүченең дәрәҗәсен белдерү очраклары да теркәлгән: йарлығ келди әй Салих билүр ердүк сениң қәүмиң моғҗизаны қулғайлар биз аны бу таш ичиндәануқлаб турурбыз сен доға қылғыл биз берәлиң [А13.7.8] һ.б. бизләр варианты исә 18 тапкыр теркәлгән: зиндан халқы әйдиләр әй Йосуф бизләр сәни сөвермиз [87v.8] һ.б.

Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә I зат алмашлыгының من – *мән* ~ بن – *бән* ~ مين – *мин* вариантлары теркәлгән: мән алты йәшәр әрдим [24.17]; бәне һәлақ қылмаңыз [356.2]; бу йармаклар мәним турур [287.17], мине чықармады [356.16]; بيز – *биз* алмашлыгы 350 мәртәбә, шулай ук بيزلر – *бизләр* уйгур формасы да шактый еш кулланылган, ул 146 мәртәбә теркәлгән: биз әйдүк йә Сахип билмәдүк, бизгә бәйан қылғыл [309.11]; бизләр: бизләр муғайын билдүк ким бу иш Мәрван ише турур [132.7] һ.б.

Котбның «Хөсрәү үә Ширин» текстында исә I затның من – *мән* формасы гына очрый: мәним қанымны сүт тег төкмә нәгаһ [10v/16], ол падишаһ мән бир гәда мән [57v/20], күчүм йитмишчә мән һәм мәдх әйайым [7r-21]; بيز биз, бизләр: җәваб айды муны һәм биз ешиттүк [106v/15]; бу мүшкил ишни бизгә шәрих қылса [17v/12]; аны хақ бизгә айтыб қылды агаһ [107v/6]; ким ош биз тег бизә ким йығлайысар [113v/15]; бизә қуллуқдын өзгә тегмәз фузуллуқ [3v/18] һ.б.

«Кисекбаш» әсәрендә I затның берлеге من – *мән*, күплеге بيز – *биз* төрле килеш кушымчалары алып төрләнгән: Ғәли әйтүр йә рәсүл мән барайын [59]; Ғәйсә бирлә мән намаз қылур ирдим [58]; йә мән өләм йә девниң башын кесәм [73] һ.б.; биз: биз ки мәгәр бу қыйуғда өлкәймиз [235]; бу қыйуғдан биз нә хәйлә қылалым [232]; мунлар әйди йа Ғәли биз нетәлим [231] һ.б.

II зат берлек саны әңгәмәдәшкә мөрәҗәгать итү өчен, күплек саны аерым төркемгә һәм билгеле затка хөрмәт белән мөрәҗәгать иткәндә кулланыла. Мисаллар:

«Кыйссасел-әнбия»дә:

سن – *сән:* сән ни қуш турурсын [А9.12], сәниң кәламуңни оларға оқы**с**ун [А516.20], сәңә иләүчлиқ доғасын қылайын [А518.14] һ.б.;

сиздин хошнудмән [А7.13], ол нирсәни мен билүрмин сизләр билмәссиз [А9.21] һ.б.;

Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә түбәндәге зат алмашлыклары кулланылыш тапкан:

II зат: *син:* синиң сүзүң [277.17]; бу күшк сәниң әрди [365.12]; нәтәк сәниң болур [258.2]; бу йармақ синең болғай [257.17]; сиз: сиз олу йашлы турурсыз [17.1]; сизиң хақыңызны сақлап иктихақ қылдым [361.17] ~ сизләр: сизләрдә қайу бириңиз йаман иш күрәр болсаңыз ул ишне тәғғайыр қылсун [303.1];

«Хөсрәү вә Ширин» текстыннан алынган мисалларга игътибар итик:

II зат: *сән:* сәни мендин аҙыгмасун Уғаным [34v/9], сән олтур шадумән [14 r.15]; сиз: чықыб сиз таш ешикдә олтуруңуз [80v/8]; қонақмән теди шаһ кәлгинчә сизгә [25v/8]; кәлиб Хосрәү айытғай сизгә барча [25v/5] һ.б.

III зат: *ол; олар, алар, анлар:* оларның қатығланмышы бирлә[5v/14]; алар ширин ерүр һәм санма Ширин [86v/2]; ешитти ерсә ход анлар бу сөзни [35v/12], аңа тең ерди тобрақ бирлә алтун [73v/18]; Уған фаслы билә берүр аңа тол [14v/19]; аңар ош анда не тузлуғ не тузсуз [102v/7]; сачар шәкәр аңар ол шәкәрстан [12v/10], тәлим өгрәнди ачығ сөз андын [56v/6] һ.б.

«Кисекбаш» әсәрендә зат алмашлыкларының кулланылышы түбәндәгечә:

II зат: *сән*: имди сән уйур девни өлтүрерсин [166]; сән текиргил ғәҗизләр морадына [268]; Тәңри арсланым теди сәни вәли [162]; сәнмү кестүң барча девләр башыны, сәнмү төктүң мунча девләр қаныны [175, 176]; сиз: Ғәли әйди ким теди мәни сизә [143]; Ғәли әйди сиз тутуң һиммәтләри [237] һ.б.

III зат اول – *ол:* сәңа маллық ол берди йана йети қат көкни вә йети қат йерни ол йаратты [КР16.15, Б214.4]; аның, аңа, аны, андын: аның елкиндә һәлақ болғай [КР. 8.8], аңа вәғдә қылың [КР. 6.10], аны қорбан қылайын теб [КР. 509.6]; اولر بولر – *олар*, بولر – булар: олар айды бизгә бу тәңри керәкмәз [А7.19], булар кәфирликдә турур [А11.20] һ.б.

III зат: ул Нәчә мәлик вәзире әрди аңар таш тәкмәди [43.4]; анлар, мунлар: анларга җауап әйде [350.1]; мунлар үнәмәделәр [367.11] һ.б.

«Кисекбаш китабы»нда III зат берлек һәм күплек сан зат алмашлыгы теркәлмәгән.

*Күрсәтү алмашлыклары.* Истәлекләрдә традицион әдәби телдә *бу, ол, о, ошбу, ош, мундаг, шөйлә, ушал, андаг, мунча, анча* кебек алмашлыклар кулланылган. Күрсәтү алмашлыклары, зат алмашлыклары кебек үк, контекстта исемләшеп, килешләр белән төрләнәләр. Аларның төп функциясе – предметларга төбәп күрсәтү аша аларны билгеләү. *Ол* сүзе бер үк вакытта III зат алмашлыгы һәм күрсәтү алмашлыгы булып йөри. Мисаллар:

«Кыйссасел-әнбия» әсәрендә күрсәтү алмашлыкларының кулланылышын күзәтик: бу душман бирлә туқушса [А7.2], бу сыйфатлық оғлан тоғса... [А7.11], муңа сәҗдә қылың [А7.14], мунда Мәүлиғә шукр қылыб тағәт қылурмын [А17.14]; ол үңүргә келди [А9.2], ошбу ташдын бир инкән чықарғыл [А13.5]; ол бутға хадәм қылдылар [А8.6]; Исхак ол етни йеди ерсә Йағқуб ол доғаны кылды [А518.20]; аны қабул қылдылар [А13.17].

*Бу, ошбу, ол, анлар* күрсәтү алмашлыклары «Нәһҗел-фәрадис» әсәре телендә предметларның, затның пространствога мөнәсәбәтен төбәп күрсәтү аша билгеләргә мөмкинлек бирә. *Бу, ушбу* – якында, билгеле булган, *ол* алмашлыгы исә ерактарак урнашкан предметка яки затка ишарә итә. Чагыштыр: бу бағны бу қуллар бирлә сизгә бағышладым [246.17]; ушбу дөнйа тигәнем бу турур [393]; мәғнәсе ол булур [92].

*О* һәм *ош* алмашлыклары сирәк теркәлгән: суалем сәңә о турур [400]; ош қарендашең Габбас иман кәлтүрде [7]. *Бу* алмашлыгы, төрләнгәндә, *мун-* формасын ала: муны [32.9], мунуң [260.9], мунда [133.10], мунлар, булар банлар һ.б.

«Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә түбәндәге күрсәтү алмашлыклары теркәлде: *бу, ол* – اوشبو – ошбу, اوشول – *ошол:* Шүкүрләр қылды сәвнүб бу түшиндин [11v/7]; көңүлләр қансу теб бу сафи сувдын [7v/15]; ол ел учтмах ерүр ол фитнәләр хур [13v/2]; бу төртинч Али ол әрәнләр башы [5v/6].

Бу алмашлыгы, төрләнгәндә, *му ~ бу* вариантын ала: *мунуң, муңа, муңар, муны, мундин, мунда, буларның:* не қылайын муңа мән теб қылу аһ [109v/2]; ант билмәзмән ош һич мундын әдгү [64v/5]; ~ буларның хош нәвасын тыңлайу шаһ [95v/3]; буларны сат ишингә харыҗ қылғыл [61v/11]; дад алур мунлар фырақын [37v/16].

اوشبو – *ошбу*, اوشول – *ошол:* буйурды ким ошол муғны оқуң теб [17v/11]; ханым атынға ошбу парси тилни чәвүрдүм [7v/14]; муғаттәл болды Хосрәв ошбу ишдин [13v/14]; ошол күндин берү ғақлын йетүрмиш [19v/4], қулуң мән тейү айды шол иҗимгә [31v/16].

*Андан, андын, анын, анда, антег, андаѓ, мундин, мунда, мунтег, мундаѓ:* тылсым қыл ким ақсун кәлсүн андан [60v/2]; ош андын ким бу сурат болды ешим [18v/16]; анын бәлгүт ханынға бу өзүңни [22v/9]; кәлүр ош анда оқ күн бирлә түни [27v/15], анча имгәтмә өзүңни [10v/3].

*Мунча*: рәвамуким мени мунча қыйнарсән [43v/5]; қоҙуб гәнҗ издәр ерди мунча мүддәт [39v/11], бир анчадин соң анлар көтүрүб баш тәлим йуғладылар [33v/20]; бу мунчаның бақма сән ташынға [2v/21].

*Сорау алмашлыклары.* Сорау алмашлыклары борынгы төрки телдән үк килә торган тамыр алмашлыклар كيم – *ким*, ني – *ни* ~ نه – *нә*, *ка-* нигезендә формалашкан, текстта сораулы сөйләм оештыру өчен кулланылган. Истәлекләр телендә *ким* сорау алмашлыгы еш очрый. «Нәһҗел-фәрадис» текстында – 195 мәртәбә, «Кыйссасел-әнбия» әсәрендә – 468 мәртәбә. Әлеге алмашлыкның күплеге *кимләр* «Нәһҗел-фәрадис» истәлегендә – 17, «Кыйссасел-әнбия» дә исә 9 мәртәбә теркәлгән. Турыдан-туры кеше мәгънәсендә йөртелгән *кемирсә* формасы исә «Нәһҗел-фәрадис» тексты телендә – 600, «Кыйссасел-әнбия» текстында 348 тапкыр кулланылыш тапкан.

*Ким* алмашлыгы затны алмаштырып килә һәм функцияләре белән зат алмашлыгына якын тора. Мисаллар: «Кыйссасел-әнбия»дә: Иблис фәриштәләрдин ешитти ким бу Кәсүр уруғындын бир пәйғамбәр болғай [А8.7], билдиләр ким ғаҙаб йетилмиш [16.13], йетмиш йыл болды мен Зүһрә йулдузға тапунурмен улашу бу сақынычда мен бу едиз көкни тиргүксиз ким тутур йағыз йирни сув үзә ким сақлайур йулдузларны ким туғурур ким батунур күндүзни ким иләтүр түннү ким кәлтүрүр бу ишләрни қамуғ сәниң тәңриң қырур әрмиш [46.1]; «Кисекбаш китабы»ннан: сәни мунда ким бирип иҙди мага [170.8] һ.б.

نه – *нә* алмашлыгы кешедән башка тереклек ияләренә һәм җансыз предметларга мөнәсәбәттә кулланыла: *нә* алмашлыгы текстта тамыр хәлендә дә һәм аның нигезендә төрле сорау алмашлыклары ясалып та кулланыла. «Кыйссасел-әнбия» истәлегеннән мисаллар: ни тиләйүрсиз [А12.17], мен аны өлтүрсәм бу халаық меңа нә бергәйләр [А18.1]; Нуд қавми иман келтүрмәди нә бәлаләр берди [А12.14], меңа ни җаза бергүси [А9.14]. «Җөмҗөмә солтан» истәлегеннән: нә туз икмәк көңлини белмәмеш [57:10]; һәрким ирсә нә иксә ургай аны [61:22] һ.б.

نجه – *нәчә* (нәчә кәссәләр анча бүтә турур [НФ. 66.15], имам Шәфиғиниң нәчә дәрәм борчы қалды [НФ. 205.4]; ол килтүргән киши нәчәмә дәрхост қылды әрсә һич нәрсә қабул қылмады [НФ. 193.5],

ничә күнгә тәқый йимәде [НФ. 235.15], ничә алтун кәрәк [НФ. 20.1], йә ана ничәгә сатайын [НФ. 342.3].

نتك – *нәтәк*: нәтәк әхуәлем нәтәк болғай [НФ. 89.5], нәтәк қылайын [НФ. 7.12], мәндин башқа нәтәк тапшурдығыз [НФ. 203.6]; әй оғлум нәтәк сабыр қылғайсын [КР. 512.6], мениң боғузумны нәтәк кесәр [КР. 513.5], иҙи йарлығы нәтәк ерсә андағ қылғыл [КР. 512.4].

نشا – *нәшә* ~ نيشا– *нишә* алмашлыгының еш кулланылуы Алтын Урда чоры әдәби телдә актив лексик берәмлек булуын раслый, мәсәлән «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә 78 мәртәбә теркәлгән: нәшә айәләм нәшә йылайурсән [НФ. 238.6], нәшә йәмәзсиз [НФ. 297.15]; нишә йарлықамады [НФ. 232.5], аңар нишә кирмәккә дастур бирилип турур [НФ. 302.6];

نجوك – нәчүк: мән нәчүк йығламағайын [НФ. 275.1], нәчүк кәфер болғай [НФ. 368.8]; сән нәчүк шақый тип әйтүрсән [НФ. 344.16];

نيما – нимә ~ نما – нәмә: син нимә йаман киши турур [НФ. 376.4]; тоны нәмә узун тон турур [НФ. 386.14]; уйаң оғлы нәмә улуғ мәлик болды [НФ. 50.11] һ.б.

نلوك – *нәлүк*: нәлүк келмәдиң [КР. 9.5], тумшуқуң нәлүк сарығ [КР. 9.15].

Сорау алмашлыкларының бер өлеше қа- нигезендә формалашкан, қан- борынгы тамыры белән бәйле алмашлыклар истәлекләр телендә тотрыклы сакланган. Мисаллар:

قج – *кач*: қач күн кәлмишдә кәҙин нәрсә алып қызлар көргәлү кәлди [КР. 27v.16], анасы қач күндә кәлип сүт бәрип турур әрди [КР. 38r.12]; қач айамда бүтгәй [НФ. 3326]; андин соң бир қач айамнар кичти [НФ. 9.5];

قجان – *қачан*: қачан Мәүлигә йаздылар әрсә оларны китерди [КР. 4v.15], қачан мөэмин туқ қарын бирлә йатур [НФ. 268.10]; қачан көрсәң [НФ. 304.6];

قنجا – *қанча*: әй ғабид қанча барурсән [НФ. 410.3, 411.1], Иләһи қанча барайын [КР. 45r.8]; атаң сәни қанча илтүр [КР. 50v.17].

قندا–*қанда*: қанда барурсен [КР. 12r.16]; қанда барурсыз [НФ. 106.3].

қандин: уғланны қандин алдың [КР. 33r.9]; Йусуфны қандин тапалың [КР. 101r.16]; булар қандин кәлди [НФ. 126.5]; әй ана бу сүтни қандин хасыйл қылдыңыз [НФ. 298.9].

قاني – *қани*: ол оғрылық қылды тәгән қарындашымыз қани [КР. 102v.11], ол көрүклүг йигитлигиң қани [КР. 108v.15], қани сизиң араңызда ала атлығ ақ тонлуғәрәнләр [НФ. 73.1], қани Хәсән Хөсәйин [НФ. 172.10].

قايو – *қайу*: Моули Тәғалә кайу қавмғә пәйғамбәр иҙсә олардин оқ иҙәр [А12.6], қайу ата оғулны қорбан қылмыш бар [КР. 511.12]; билмәсмән қайу йанға бардылар [НФ. 172.12]; қайу иш мәслихәт болас [НФ. 174.2]; бу нурлар қайу тарафқа ким барды [НФ. 30.10] һ.б.

Истәлекләр телендә теркәлгән сорау алмашлыкларын шул рәвешле өйрәнү язма истәлекләр телендә шактый үзенчәлекле, борынгы төрки чор ядкәрләр өчен хас алмашлыкларның актив кулланылышта йөрүен күрсәтә. Бу күренеш исә Алтын Урда чорында борынгы төрки традицион әдәби теленең тотрыклы дәвам итүе турында сөйли.

*Билгеләү алмашлыклары.* Истәлекләр телендә борынгы төрки әдәби телдән килгән كندو – *кәндү*, اوز – *өз* билгеләү алмашлыклары актив кулланыла. *Кәндү* һәм *үз* алмашлыклары, нигездә бер үк мәгънә белдерәләр, текстта кушма төрләре дә очрый. Тамыр хәлендә предметларны һәм затны ачыклап, аергыч ролендә килүләре теркәлгән: қара булут йағынлық болур тип аны қолды ол кәндү ғазаб булуты әрмиш [КР. 60.4]; кәндүнә рәхим қылмаған даим қутртула билмәс ол мәшәққәтдән [Гб 92а.5]; шаһ өз адлы үзә турдыса дайим [ХШ. 9v.10], ақлы келди кәндүнә ачды көзин [Кб. 139.31] һ.б.

«Кыйссасел-әнбия» истәлегендә *кәндү* алмашлыгы – 27, «Нәһҗелфәрадис» әсәрендә – 4, «Гөлестан бит-төрки»дә бер мәртәбә теркәлде. *Өз* алмашлыгының еш кулланылуы, *кәнд* алмашлыгының берәр мисалда гына теркәлүе билгеләнде. *Үз* алмашлыгы нигез формасында сирәк кулланылган, күпчелек очракта тартым белән формалашкан, килеш белән дә төрләнә:

Билгеләү алмашлыклары мәгънәсендә кулланыла торган *қаму ~ қамуг, барча, җөмлә* сүзләрен, шулай ук һәр сүзе катнашында ясалган алмашлыкларны билгеләргә мөмкин.

قموغ – *қамуг*: қамуғ ғаибләрини кичүргәймин [КР. 515.15], ғәраб қамуғы Исмәғил уруғы турурлар [А.508.3], әгәр қамуғы йипәк болса әрди [НФ. 245.16], қамуғ йөнләрни аңлаб болды агаһ [ХШ. 8v.17] һ.б.

## 2.6. Фигыль

Алтын Урда чоры язма истәлекләре телендә фигыль күп төрле грамматик формаларда теркәлгән катлаулы сүз төркемен тәшкил итә. Фигыльнең грамматик категорияләре аның төрле төркемчәләрендә чагылыш таба. Зат-сан белән төрләнү-төрләнмәүләренә бәйле затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр төркемчәсе аерылып чыгарыла.

Тикшерелә торган чыганакларда затланышлы фигыльләрнең истәлекләрдә хикәяләү, боеру, теләк, шарт наклонениеләре кулланылган. Затланышсыз фигыльләрдә эшнең үтәүчесе махсус зат-сан кушымчалары белән белдерелми. Әдәби текстларда сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль төркемчәләре очрый.

Алтын Урда чоры язма истәлекләрендә урын алган фигыль формаларының кулланылыш үзенчәлеген өйрәнү чыганаклардагы әдәби телнең нигезен билгеләү өчен әһәмиятле. Истәлекләр телендәге фигыль формалары Әмир Нәҗип, Я.С. Әхмәтгалиева, Ф.М. Хисамова, Ф.Ш. Нуриева, А.Р. Исхакова, Г.Ф. Гайнуллина, А.И. Исламова тарафыннан өйрәнелгән.

Төрки телләрдә фигыль сүз төркеменең һәм аның төп грамматик категорияләренең формалашуы турындагы карашлар бу өлкәгә караган башка хезмәтләрдә дә шактый эзлекле яктыртыла. Галимнәр фикеренчә, күпчелек төрки чордагы язма истәлекләрдәге кебек, бу язмаларда да грамматик формалар катнаш хәлдә кулланыла. Алтын Урда чорында язылган әсәрләр нигезендә, борынгы төрки әдәби телгә хас традицион формалар белән бергә, шул чор гомумхалык сөйләм теле өчен хас тел нормаларын ачыкларга мөмкинлек бирә.

### 2.6.1. Затланышлы фигыль формалары

*Хикәя фигыль.* Хикәя фигыльләр әдәби истәлекләр телендә, күп төрле заман формалары булган шактый катлаулы фигыль системасын тәшкил итә. Аларны фәндә кабул ителгәнчә, өч объектив заманга туплап күрсәтергә мөмкин: үткән заман, хәзерге-киләчәк заман, киләчәк заман. Заманнар синтетик, ягъни кушымчалау һәм аналитик юл белән ясалалар.

Үткән заман формалары. Истәлекләр телендә үткән заман хикәя фигыльнең *-ды/-ди, -ты/-ти, -мыш/-миш, -ган* формалары кулланылган.

*-ды/-ди, -ты/-ти* кушымчалы үткән заман хикәя фигыль язма истәлекләрдә гаять актив кулланылган. Билгеле (категорик) үткән заман дип йөртелә торган *-ды/-де* кушымчалы үткән заман хикәя фигыль килеп чыгышы буенча иң борынгы төрки нигез телгә нисбәтләнә һәм хәзерге барлык төрки телләрдә гамәлдә йөри. Кулланылышы буенча әлеге заман формасы бер функцияле, үткәндә сөйләүченең күз алдында булган, аның тәгаен үтәлгәнлеге сөйләүчегә мәгълүм булган эш-хәлне белдерә. Бу заман формасының тулы төрләнеш парадигмасы теркәлгән. Мисаллар:

«Кыйссасел-әнбия» әсәрендә I зат берлектә һәм күплектә, II зат берлектә *-ды/-де* кушымчасы күбрәк иренләшкән вариантта кулланыла: *-дум/-дүм, -дук/-дүк, -дуң,* иренләшмәгән вариант чагыштырмача сирәк очрый: зиндандин қуртулдум (قورتولدوم) бир кичә мунда йатурмын [8.6]; ош кәдик ити ош кәлтүрдүм (كلتوردوم) [518.20]; үч кишини болдум (بولدوم) [18.7] һ.б.

I зат күплеге *-дуқ/-дүк, -дымыз* аффикслары ала: бир анча халық бирлә кимәгә кирдүк (كيردوک) [17.16]; үч ғаибини әйдүк (ايدوک) [140.2]; он сәкиз йармаққа саттуқ (ستتوق) [140.12]; ايشيتدوک – ишитдүк [116.5]; تيدوک – тидүк [103.20]; бизләр бу илгә йаманлық қылмадуқ (قلمادوق) [185.7]; *-дымыз:* الدمز – алдымыз [73.6]; تديمز – тедимиз [226.12]; ايشيتديمز – ишитдимиз [120.9]; اولتورديميز – зөлтүрдимиз [36.2] һ.б.

II зат берлек сан *-дың/-дуң* формасында килә: бу оғланны қайдин الدور – алдың [10.1]; әй Ибраһим түшиңни күнигә (جيقاردنک) чықардың [513.20]; اولتوردنک – өлтүрдиң [17r.6] ~ اولتوردونک – өлтүрдүң [21r.10]; يوريتدونک – йүритдүң [12v.9]; بولدونک – болдуң [11v.13], мунча йыл болды мәңа нәлүк كالمادينک – кәлмәдиң [8.5] һ.б.

II зат күплек *-дыңыз/-дуңуз* кушымчалары белән ясалган: қайү йағы бу ишни қылғай ким өзүңүзгә قيلدينكز – қылдыңыз [7.18]; بردينكيز – бердиңиз [10.7]; كوردونكوز – көрдүңүз [98.18]; ايشيتتينكيز – ишиттиңиз [200.9]; بولدونكوز – болдуңуз [223.15] ~ بلدينكز болдыңыз [196.1] һ.б.

III зат берлек сан *-ды/-де* формасында килә, саңгыраулыкта ярашып *-ты/-ти* белән тәгъбир ителеше теркәлгән: бүгүн шәриғәтдә әр бәһасы йүз тевә андин қалды [509.17]; онунчы Ғабдулла тоғды әӡин анадин [509.5]; бәзни туқушға кимишти [7.19]; андын қорқуб башым ақарды [13.7]; йөрүтди [3.1]; йетти ~ йетди [39.1], йүриди түн күндүзин [5.7]; Салих оларны иманға үндәди ғазабдин қурқутды оҗмахға үмид бәрди [12.8] һ.б.

III зат күплеге *-ды + лар, -ди + ләр* белән тәгъбир ителә: барча буғун аны таңлаб көрдиләр [5.10]; кишиләр йығылыб кәлдиләр асрамақға алур болдылар [10.8]; көрүштиләр [226.14]; үзләриңә гүр қазыдылар, кәфинләрин кидиләр, гүрләринә олтурдылар [17.3]; үч йүз кишидин артуқ мөсүлман болмадылар [11.18]; бир анчасы иман кәлтүрмәдиләр [13.12] һ.б. III зат аффикслары берлектә дә, күплектә дә иренләшкән вариантта килми.

*-мыш* кушымчалы заман текстларда үткәндә булган вакыйгаларны тасвирлау өчен кулланылган, сөйләүченең үзенең күрмәгәнлеге, кешедән ишетеп сөйләү кебек мәгънәсе белдерелгән. Текстта

бары III затның берлек һәм күплек саннары теркәлгән: йүзләри қарармыш көрдиләр ирсә [17.2]; қамуғларының йүзләри сарғармыш [16.12]; билдиләр ким ғазаб итилмиш [16.13]; жаду ирмиш сән тиб иман кәлтүрмәдиләр [13.11], риуәйатдә кәлмиш ол тоқуз киши бөзчи ирдиләр [14.15], түрлүк чичәк ачылмыш ниғмәтләр хасил болмыш [15.19] һ.б.

Текстта *-мыш бар* формасы кулланылган: ата оғлыны қорбан қылмыш бар [51.6, 511.12].

*-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы үткән заман хикәя фигыль «Нәһҗелфәрадис» әсәрендә актив кулланылган.

I зат берлектә: мән сәни андаз сақындым (ساقيندیز) [42.8]; мән бу битикни битимәдим (بيتيماديم) [13.4]; اولتورديم – үлтүрдим [335.16]; I зат күплеге *-дымыз, -дуқ/-дик, -туқ/-тик:* бир күн тәғам бәшүрдүк (بشردوق) һич татмады [25.8]; андин суң һаваға аштуқ (اشتوق) әлик қат күккә йәттүк (يتّوک) [53.7]; باغلادوق – збағладуқ [126.10]; باردوق – бардуқ [126.10]; بولدوق – болдуқ [77.1]; قيلدوق – қылдуқ [2.9]; بيلدوک – билдүк [4.6]; اولتوردوک – үлтүрдүк [358.11]; قويدوق – қойдуқ [58.16]; قودوق – қодуқ; کيتاردوک – китәрдүк [33.3];

*-дымыз:* сиз уйқуңуз ичиндә үкүш йиғладыңыз (يغلادينکيز) әрсә бизләр тәқый сизгә күрә йиғладымыз (يغلاديميز ) [103.8].

II зат берлектә *-дың/-диң* кушымчасы күбрәк иренләшмәгән вариантта килә: нәшә мундағ ишкә қасд қылдың мини хақламадың (خاقلامادينک) [61.16]; муны қандин (اوکراندينک) үгрәндиң [32.9]; менин атамны тагы ер қарындашумны үлтүрдүң (اولتوردونک) [34.6]; II зат күплеге *-дыңыз/-дуңуз:* нишә қапуғ сақламадыңыз (سقلامادينکيز) [136.6]; мәни қодылар тәқы мән сизгә бардым сиз мини үзүңүзгә сығындурдуңуз (سغندوردونکوز) [76.14]; пәйғамбәрзадәни үлтүрдүңүз шәһид қылдыңыз (قيلدينکيز) [170.1] һ.б.

III зат берлек сан *-ды/-ди, -ты/-ти* вариантларында теркәлгән: Фатыйма үз илки бирлә арпа үкүди (اوکودی) тәқый әтмәк бәшүрди (بشوردی) [141.7]; Салихның күңлинкә қурқуғ түшти (توشتی) тәқы қазғурды (قذغوردی) [166.11]; тевеси чүкти (جوکتی) [40.15]; ол қачты (قجتی ) [43.4];

III зат күплеге *-ды+лар, -ты+лар* белән тәгъбир ителә: бардылар (بردی لار) бир чуқур қазыдылар (قزدی لار) [34.7]; бизләр сувсадуқ хайванлар тәқый сувсадылар (سفسادی لار) [44.1]; күк қапығыны ачтылар (اجتی لار ) [53.9].

Нәтиҗәле үткән заманның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә *-мыш, -ган турур, -ып турур* формалары теркәлгән.

*-мыш* кушымчалы заман текстларда сөйләүченең үзенең күрмәгәнлеге, кешедән ишетеп сөйләү кебек мәгънәсе белдерелгән. Текстта бары III затның берлек һәм күплек саннары кулланылыш тапкан: китабында бу хәдис кәлтүрмиш (کلتورمیش) [3.3]; бакар анасы тонларыны кәзмиш (کزمیش) төшәгини йағмыш (یغمیش) [221.15]; Фатыйманы күрәр қарны арқасынға йәбшүнмиш (بیشونمیش) ики күзи чуқур булмуш инкән зағиф болмыш (بولمیش) [142.13]; сизиң чәрик меним ики йүз тивәмни алмышлар (المیش لار) [42.7]; мәккәниң улуғлары қул қуштуруп хүрмәт мәқаминдә туруқмышлар (تروقمیش لار) [51.3].

Кыпчак телләренә хас булган *-ган* күрсәткеченең әдәби телгә килеп керүен шул чор сөйләм тел тәэсире дип аңлатып була. Үткәндә булган вакыйгаларны тасвирлау, перфект мәгънәсен көчәйтү өчен *турур* ярдәмче фигыль белән III затның берлек санында кулланылган: Хақиқатта Тәңри Тәғәлә بیلغان билгән турур сизиң әхвәлиңизни тәқый һәм билгән турур синиң сирләриңизни; Хақ тәғалә қулларының йазуқларын үрткән (اورتکان) турур тәқый рәхмәт қылған (قیلغان) турур [313-9]; Госман инкән офтанған (اوفتانغان) урур [123.4, 75.1] һ.б. Юклыгы *-ган* әрмәс формасы белән белдерелгән: Пәйғамбәр әйтүр мен оқыған (اوقیفان) әрмишмән [75.1]. *-ган* сөйләм теленә хас форма әдәби телгә нәкъ Алтын Урда чорында үтеп керә башлаган дип карау дөрес булыр.

*-ып турур* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман текстта сирәк кабатлана: икки теве сатғын алып турур (الب تورور) мән сәкиз йармаққа [46]; хатунуң сачыны (کسیب تورور) кәсип турур ушбу сәғәт килсә күрәрсән [332] һ.б.

«Җөмҗөмә солтан» әсәрендә категорик үткән заман *-ды, -ты* кушымчалары актив кулланылган (219 мәртәбә теркәлгән), 2 төр зат кушымчалары алып төрләнгән: جیقتیم – чықтым [6.21]; توشتوم – түштүм [6.27]; کوردیم – күрдим [7.12]; انانمادیق – инанмадық [13.5]; کوردونک – үрдүң [17.6]; سوردینک – сордың [5.37]; کیلدینک – килдиң [1.31]; کیلدینکیز – қылдыңыз [19.10]; باردی – барды [6.23], بوشادی – бушады [7.1]; توتدیلار – тутдылар [15.12] һ.б.

*-мыш* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман текстта үткәндә булган вакыйгаларны тасвирлау өчен кулланылган (24 мәртәбә теркәлгән): یاتمیشمین – йатмышмын [7.34], бир улуғ сахра болмыш (بولمیش) бу җиһан [18.19], بیرمامیش – бирмәмиш [11], قالمامیش – қалмамыш [2], کیدیرمیش – кидермәмиш [11], ساقلامامیش – сақламамыш [11] һ.б.

«Кисекбаш китабы»нда: I зат берлектә: باردیم – бардым [119]; تیمادیم – темәдим [205]; ییمادیم – йимәдим [206]; I зат күплек: теркәлмәгән;

II зат берлектә: كيلدينک – келдиң [173];كستونک – кестүң [175]; توكتونک – түктүң [176]; II зат күплек: теркәлмәгән; III зат берлек:اجدى – ачды [125] ~اجتى – ачты [215]; اشتتى – әшитти [209], توكدى – түкди [24]; اوردى – орды [31];مندى – мәнди [83];باغلادى – бағлады [83]; قورقتى – қорқты [33]; III зат күплек: اوزاتتى لار – узаттылар [85];قايتتى لار – қайттылар [88]; يتدى لار – йетдиләр [100] һ.б. Тартыклар ассимиляциясе нигездә саклана, сирәк саңгырау тартыклар янында яңгырау вариант килергә мөмкин: باتدى – батды [193]; يتدى لار – йетдиләр [100]; اجدى – ачды [125].

Язучы үткәндә күз алдында булган, аның тәгаен үтәлгәнлеге сөйләүчегә мәгълүм булган эш-хәлләрнең кискенлеген, кинәтлеген белдерү өчен әлеге формаларны унар мәртәбә кабатлаган җөмләләр теркәлгән: алды күрси хамла қылды Ғәлигә Ғәли тәқы қалқан алды илинә әйлә орды дев Ғәлигә күрзини кем Ғәли батды йергә тезитени һич тәғәйир болмады ол шаһ вәли сачрады менди ол дәм таш үстүнә шүкүр қылды сәҗдә етди достуна [189.197]; ақлы келди күңлүнә ачды күзин сәждаға барды Хақға орды йүзин сәжда қылды Тәңригә Ғәли тапуғ Ғәли бақты күрди бир темүр қапуғ тартты қолорды күрди улуғ сарай [125.129].

*-мыш* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман текстта сирәк, 6 мәртәбә теркәлгән: зира ким Алла дидарын күрмишим, мурадымға мақсудумға текмишим [47,48]; йузниң күрки сарайға нур әйләмиш тәңри ашқы жаныға кәр әйләмиш [131.132]; күз йәши саждә йерини болғамыш [136].

*-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы үткән заман хикәя фигыль «Хөсрәү вә Ширин» текстында шулай ук актив кулланылган, 4306 мәртәбә кабатланган: I зат берлектә: йаздым [18r]; күрдүм [21v]; кездим [18r]; йордум [21v]; билдим [18r]; келдим [19v]; сәвүндүм [24v]; қылдым [24r]; кутулдум [72v]; айыттым [72v]; йаздым [18r]; қалдым [24v]; қойдым [24v]; ишиттим [23v]; мендим [24r]; турмәдым [24v]; билмәдим [25r] һ.б.

I зат күплеге чагыштырмача сирәк теркәлгән: күрмәдүк [204]; қылмадуқ [234]; қалдуқ [110r].

II зат берлектә: табтың [22v]; кетәрдиң [21r]; күтәрдиң [21r]; қолдуң [21r]; болдуң [21r]; түштүң [21r]; киттиң [21r]; билдиң [9]; тутмадуң [171.2]; II зат күплектә: йырақдын кәлдиңиз бир туруңуз [164.5.214]; ешиттиңиз [129.20.171] һ.б.

III зат берлектә: күнди [18]; тыңлады [21]; башлады [18]; айтты [18]; үпти [18]; қопты [18]; туты [18]; ачты [20]; түсти [24]; қалмады [19];

III зат күплектә: туруқтылар [25, 20]; сулатылар [72], таңладылар [21]; йығылдылар [20]; бағладылар [20]; тәбрәдиләр [20]; қайттылар

[21]; келдиләр [21] һ.б. Тартыклар ассимиляциясе орфографиядә эзлекле сакланган. Җөмләдә тиңдәш хәбәрләр категорик үткән заман хикәя фигыль формасында еш очрый: тейү сақшаб күңүл бир йару қылды атанға қамчы урды, сүрди, йелдиол айны күтүрүб шәб тиз ушты пәри йаңлығ партны алды қачты йана шаһ чықты болғай тейү бақыаны күнмәди жанын отқа йақты [24r .9]; хайалыңқа табунмақдын бу қалдым сени теб ошбу хасрәт ичрә қалдым қарансызлықда ешикиң дә раһтым қатығ күзлүқ қулуб мундағ быpақтум [97r] һ.б.

Кыпчак телләренә хас булган *-ган* күрсәткече бары III зат берлек санда очрый, 16 мәртәбә теркәлгән: фәләкни тәзгитиб йулдуз йүриткән қамуғны хүкми бирлә һәм игиткән бу мунча ғилм vә һикмәтләр йаратған қаранғу түнни күн бирлә йарутған [2r8.12]; бу хидмәткә кәлиб шүкр аймаған ким [15.20]; йаратған йерни күкни ай вә кәкни / йарутған қүдрәти бирлә ажунны [144.7]; йалғуз бақи қалған [160.3] һ.б.

*-мыш* кушымчалы заман текстларда үткәндә булган вакыйгаларны тасвирлау өчен шактый иркен кулланылган, 236 мәртәбә кабатланган (чагыштыр: *-ды* – 4306 мәртәбә, *-ган* – 16 мәртәбә): нә шум сәғәттә чықмыш быз тейу [21v]; II зат берлектә.: әлимгә алдым әрсә от аймышсән [179.10]; қылыб күб навһа қылмышсән һәм әй бәг [141.16]; йаратылмышсән әввәл ахыр үлгүң [230.4]; III зат берлектә: хасис тушларға ол гәвһәр қатылмыш Йусуф тег қадғу қудуғунға атылмыш [30r.29.30]; миң ал бирлә килидин елдин алмыш онуң ол гәнж мунтег һош ачылмыс [23v.1,2]; иттим ғашықың быйруқ битүрмиш үңүн йуртындин ол һәм күз күтәрмиш [20r.19.20]; төшәнмиш бақлар ош ната шақайық [75.7.263]; булутлар һәм һавада йүзин ачмыш [75.11]; әдәб сақлаб нәдимләр уру турмыш [190.11]; III зат күплектә: белин бағлаб туруқмышлар бабуғда [149.20]; йығылмышлар айақдын асруб ол түн [187.19]; қубармышлар ташдын [30.12]; булар қол қавшунуб турмыш табуғда [104.9]; сабақ алмыш һавада қушлар андан [28.5].

Юклык формасы ике төрле күрсәтелгән: йузини күрмәмиш ғүмриңда бир ер [29r.19]; кисигә сунмамыш елкини ойнаб [29r.21]; мунуң тег таңсуқ иш һич болмышы йоқ киши үзүн киси һич үлмиши йоқ [113v.20, 21]; киши бағы йемишин йемишим йоқ [76v] һ.б.

*-мыш* кушымчалы заман тиңдәш хәбәр буларак җөмлә эчендә алтышар тапкыр кабатланган очраклар теркәлгән: хорослар үни бир гездин тутулмыш сүбһ сөклүни һәм отқа урулмыш түтүниндин дүнйа маламал булмыш көмүр мәшриқ йолыны күн урутмыш нә ход мәғриб чәриги йол тутмыш замана бу қулувдин оғлақ ермиш фәләк һәм қутуб

тег [Қутб] һайранқалмыш [157.17.21]; ишиттим ким аты йабанда қашмыш һумайны көтүрүб ... учмыш [60.17] һ.б.

*-ып турур* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман сирәк кулланылган. I зат берлек сан: йаратған бир идимгә йалбарыб мән ошол қылған йазуқларны аңыб мән [108r.7, 8]; бу қадғу хәсрәт үзрә олтуруб мән [169.17]; 1зат берлек сан: сачыб сачлары күлгә мүшк толуб суқа нәбүт вә қәнд вә шәкәр [21r.10, 11]; буйуруптур қулунға ол кәрим Хақ.

«Мәхәббәтнамә» әсәре телендә үткән заман хикәя фигыльнең *-ды/-де, -ты/-те, -мыш/-миш, -ган* формалары теркәлгән.

*-ды/-де, -ты/-ти* кушымчалы үткән заман хикәя фигыль. I зат берлектә: айдым [38]: башладым [60]; битидим [437]; қылдым [144]; биттим [437]; үптим [38]; болдум [436]; бойун сундум [254]; оқудум [50]; күрдүм [41]; туттум [433]; йад қылдым [1]; бунйад қылдым [1] оқудум фурсат билә болдум мәхәлни оқудум хидмәтиндә бу ғәзәлни [50]; II зат берлектә: унуттуң [172]; туттуң [72.35]; ишиттиң [156]; бирмәдиң [361]; III зат берлектә: йаратты [4, 6, 9]; бичти [45]; ашты [151]; бирди [441]; күрди [379]; үлтүрди [361]; салды [275]; сонды [168]; келтүрдиләр [121]; китмәди [110]; булмады [350]; күнүл татумады [362]; йаратқан, ким тән ичрә җан йаратты сени күрклүк ләр ханы йаратты қуйаш йаңлуғ йүзүңни йарутты фәләк тек бизни сәрдәрдан йаратты [51–52] һ.б.

*-ып турур* кушымчалы нәтиҗәле үткән заманның III зат берлек сан формасы 6 мәртәбә кабатлана: болуп тур тәлғәтингә мөштәри қул [71]; чичәк йапрақлары йиргә түшүптүр [87]; җәмалыңдин хирәд сәйда болуптур, ичим бағрым қамуқ толуптур [280]; қылыптур халықны сәйда киришмән [283]; бу дәфтәр ким болуптур Мыср кәнди [440].

*-ган* формалы үткән заманның III зат берлек сан формасы 4 мәртәбә теркәлгән: ики йакту гәвһәр ғаләмга биргән, мәхәббәт гәнҗини адәмгә биргән [2] фәләкниң дәфтәриндин түнни бойған, җиһан бунйадыны сүз үзрә қойған [3].

«Гөлестан бит-төрки» әсәрендә категорик үткән заманның тулы төрләнеш парадигмасы бар, I зат берлектә һәм күплектә, II зат берлектә *-ды/-де* кушымчасы күбрәк иренләшкән вариантта килә: *-дум/-дүм, -дук/дүк, -дуң,* иренләшмәгән вариант чагыштырмача сирәгрәк очрый: күрдүм [93v], айттым [92v], тарттум [104v], бақтым [55v], ичтим [123v], билдим [103v], туттум [29v] һ.б. كوردوم – күрдүм варианты 37 мәртәбә теркәлгән, كورديم күрдим варианты исә өч мисалда очрый; I зат күплектә: қылдуқ [178р], идүк [149r], киттик [149v] һ.б.;

II зат берлектә: түштүң [103v], алдың [183v], айттың [44v] булдуң [152r], тута билмәдиң [94v], кәтәрдүң [131r], аңладың [58r], күрдүң [18r] һ.б.;

II зат күплектә: кирәк идиңиз [47v], йиттиңиз [175r], буйурдыңыз ~ буйуртуңуз [56v], кирик идиңиз [47v] һ.б.

III зат берлектә: башлады [92r], түшти [92v], кетүрди [102v], буйурды [105v], бақты [9v], басты [38 r], ичти [58v] үпти [11 r] һ.б.; III зат күплектә: бичтиләр [93r], урдылар [102v], кетүрдиләр [104v], алдылар [92r], айттылар [12r], туттылар [11 r] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки» әсәрендә Нәтиҗәле үткән заманның *-мыш, -ган турур, -ып турур* формалары теркәлгән.

*-мыш/-миш* кушымчалы заман күбрәк III зат берлек санда теркәлгән, сирәгрәк II зат формалары очрый (2 мәртәбә кабатланган) болмышсән [111r.8], сен имишсән [69r.58]; III зат берлектә: алмыш [135r.10], битмиш [147v.11], болмыш [27v.7], қависи өлмиш [84r.12], зағифи селәмәт қалмыш [84 r.12], отурмыш [19v].

Нәтиҗәле үткән заман мәгънәсен белдерү өчен «Гөлестан бит-төрки» текстында *-ып, -ып турур* кушымчалы фигыльләр кулланылган, зат белән төрләнешенең тулы парадигмасы теркәлгән. Мисаллар:

I зат берлек сан: килип турурмән [83r .8], бырақып турурмән [142r .12], түшүнүп турурмән [19r .7], түш күрүпмән [112v.7], дин терк итипмән [70r .10, 11]; I зат күплек сан: мүрид болуп турурбыз [119r.10];

II зат берлек сан: түшүп турурсән [130 r], мескенетде қалып турурсән [82v.2], алыпсән [80р.13], дипсен [99v.13], ғаһдини бузупсән [172v.4] һ.б.

III зат берлек сан: әйтип турур [117 r .10], вида қылып турур [42 r.3], III зат күплек сан: айтып турурлар [26r.10] үгрәнип турурлар [48v.7]. Сөйләүче үзе күрмәгән, үткәндә булган эш-хәлләрне белдерү өчен кулланылган: күрди ким халық аның үзүнү йығылып турур [174], муңа не болуп турур айыттылар хамир ичип уруш етип киши үлтүрүр [174], дошман алына алданмағыл ким ол ал тузағын қуруп турур. [Мисаллар китерелә: Наджип, 1975, с. 196–197]. Билгеле үткән заман мәгънәсен белдереп тә килгән: сәниң үчүн бир түш күрүпмән хайур болғай [219].

Юклык формасында: нәрәйим ким җиһандан тоймайып мән [270], таң атқанча күзүмни йуммайып мән [118].

Үткән заман хикәя фигыльнең төп күрсәткечләре: *-ды* (претерит), *-ган (турур)* (перфект I), *-мыш* һәм *-ып (тур)* (перфект I).

*-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы үткән заман хикәя фигыль язма истәлекләрдә шактый киң кулланылган. Алар нигезендә төзелгән тиңдәш хәбәрләр зур урын тота, башлыча стилистик максат белән кулланылганнар, процессның динамикасын, я бер-бер артлы агышын бирү өчен файдаланылганнар.

Тулы төрләнеш парадигмасы теркәлгән:

I зат берлек сан:

*-дым/-дим:* чықдым, битидим;

*-дум/-дүм:* күрдүм;

*-тым/-тим:* биттим, айттым.

I зат күплек сан:

*-дуқ/-дүк:* пиширдүк, қылмадуқ;

*-туқ/-түк:* астуқ, йәттүк;

*-дымыз:* бардымыз [НФ., РБ.].

II зат берлек сан:

*-дың/-диң:* қылдуң, үгрәндиң;

*-тың/-тиң:* әшиттиң, оқуттуң.

II зат күплек сан:

*-дыңыз/-дунуз:* сақладыңыз, сығындурдуңуз.

III зат белек сан:

*-ды/-ди, -ты/-ти:* өкүди, түшти, татмады

III зат күплек сан:

*-дылар/-тылар:* суwсадылар, қайттылар.

I зат берлектә һәм күплектә, II зат берлектә *-ды/-де* кушымчасы күбрәк иренләшкән вариантта кулланыла, кушымчалар саңгыраулыкта-яңгыраулыкта ярашалар. «Кисекбаш китабы», «Җөмҗөмә солтан» әсәрләре текстында кушымча охшашланып та, охшашланмыйча да килә ала: *китди, ашды, чықды* һ.б.

Нәтиҗәле үткән заманның *-мыш, -ган турур, -ып (турур)* формалары чагыштырмача аз теркәлгән. *-мыш, -ган* формалары төрки телләрне классификацияләүдә төп күрсәткечләр булып тора, әмма тикшеренүләрдән күренгәнчә ике вариант та Алтын Урда чоры истәлекләрендә сирәк, күпчелек очракта III зат берлек санда кулланылган.

*-ган* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль барлык истәлекләрдә теркәлмәгән, фәкать М. Булгариның «Нәһҗел-фәрадис», Котбның «Хөсрәү вә Ширин» һәм Харәзминең «Мәхәббәтнамә» әсәрләрендә теркәлгән: йулдуз йүрүткән, хикмәтләр йаратқан, сүз үзрә

қойған. «Нәһҗел-фарадис»тә исә *-ган* формасының перфект мәгънәсе турур ярдәмче фигыле белән көчәйтелгән: билгән турур, офтанған турур. Халык сөйләшләренә хас кыпчак формасының әдәби телгә керә башлау моменты теркәлгән дип фаразлый алабыз.

*-ып (турур)* кушымчалы фигыль истәлекләр телендә актив кулланылган, бу заман формасының берлек санда зат белән төрләнеш парадигмасы теркәлгән. *-ып (турур)* кушымчалы фигыльнең төрле вариантларда саклануы сөйләм теле тәэсирендә әдәби телгә үтеп керүнең башлангыч этабы дип бәяләп була: тәрк етипмен [Гб.], сатгын алып турурмән [НФ.], йалбарыбмән [ХШ.], алыбсән [Гб.], түшүп турурсән [НФ.], айтып дурурлар [Гб.], түшүптүр [Мн.] һ.б.

Алтын Урда чоры язма истәлекләре телендә *-мыш, -ган турур, -ып (турур)* формаларының кулланылышын күзәтү, әдәби телгә сөйләм теленең йогынтысын, әдәби телдәге региональ үзенчәлекләрне күрергә мөмкинлек бирә.

*-р, -ар/-әр, -ур/-үр, -ыр/-ир* кушымчалы хәзерге-киләчәк заман.

*-р, -ар/-әр, -ур/-үр, -ыр/-ир* кушымчалы хикәя фигыль – борынгы төрки нигез телдән үк килгән гомумтөрки фигыль формасы.

Галимнәр *-ыр/-ер* кушымчалы фигыль формасының тарихи рәвештә һәм күпчелек төрки телләрдә, нигездә, хәзерге-киләчәк заман мәгънәсендә кулланылышын билгелиләр. Әлеге заман формасы һәр ике семантик яссылыкта, ягъни хәзерге заман мәгънәсендә һәм шулай ук киләчәк заман мәгънәсендә шактый еш кулланыла:

1) Хәзерге заманга караган, ягъни сөйләү моментында башкарыла торган эш яки хәлне белдерә. Мисаллар:

«Кыйссасел-әнбия»дә: Әйди ни болды йалғузун тәңригә табынурсән [17.11], Хаҗар әйди қунуққа барурмән тивәрсин йибни тақы бычақны ни қылурсын [510.17] һ.б.

«Нәһҗел-фәрадис» әсәреннән: бир зәғифни көрәрмән ики әлиги бағлығ [68.12]; үстүн бақтым әрсә күрәрмән бир йәрли күкли арасында бир улуғ тәхт урумыш [9.7], сиз қорқарсыз [243.3], бақармән Госмам қанқа булғасып йатур [134.15] һ.б.

«Җөмҗөмә солтан»нан: басар анлар йүзларинә қыздуруп [21а.10] һ.б.;

«Кисекбаш китабы»ннан: ол дев ойғанды та төрт йару бақар көп сөз сөзләр ағзындин отлар сачар [171, 172], қанаты бардур текәйсен ки үсәр, оқ арым дүлдүлдин илгәрү китәр [90], намаз оқур ол ахирәт хатуны аһ етәр көккә чықар һәм түтүни [146] һ.б;

«Хөсрәү вә Ширин» әсәреннән: күйәрмән һәм сызармән аркун аркун [158.14], биз имди тиләрбиз [8.11], көрәрсән һич ким ерсә елгә алмаз [51.14] һ.б.; Мн.: висалыңның бүгүн шүкрин кылурмын [351], қатында йир өбәрләр [113]; Гб.: көрди ким халаиқ суw ичәрләр [101v], не тиләр сән мәндән тиләгил [40v.6] не болды сәңа ким бу хәлдә китәрсән [26r.6] һ.б.

2) Даими, кабатланган эш-хәлләрне белдерә. Мисаллар:

«Кыйссасел-әнбия»дә: йәһүдләр Тәүрәтдә хәбәр бирүрләр [508.3], әйди тәңри йарлықы бирлә қорбан қылурман [511.6], ғәүрәтләр зәғифрәк болур тиб Хаҗәргә килди [511.10] һ.б;

«Нәһҗел-фәрадис»та: йалған сөзләмәк йавуз ишкә тәгүрүр [381.2], қараңқу түн ичиндә қара таш үзә андагы қарыбынчаның тәбрәнгәнини күрәр [229.13]; сәниң әзгү ғадәтләриң бар йақ йавуқны сәвәрсән йалған сөзләмәссән [11.5].

«Җөмҗөмә солтан»да: һәрбириниң ғаурәтиндин қан ақар [22a.3], йатурлар түнү күндүз кечәләр [40.12] һ.б.; Кб: сақалы ақ һәм йүзиндин нур ақар көзи қәмар һәр ким йүзинә бақар [30], бармақлары охшар адәм гәүдәси [150], оқур мусхафны һәр дәм хатим итәр [90].

«Хөсрәү вә Ширин»дә: күп ойунлар билүр бу аңсыз азун [198.4], кәдик тег адәмини күрсә үркәр [124.15], оқуғлы оқурда оқарур аны [233.4].

3) Киләчәк заман төсмерен белдереп килә. Әсәрләрдән үрнәкләр:

«Кыйсасел-әнбия»дә: Исхақға бу кәрамәт бәрдиң Исмәғийлгә ни бәрүрсин [518.1], сиунчи сизгә қамуғларыңыз зиндандин қутулурсыз [180.3]. 3 л. ед.ч.: көз йумуб ачғунча үч миң йыллық сийратдин кичәр [516.10], үч күнда ғағаб кәлүр [15.15]; бәз бу тевәни өлтүрмәкинчә мундин қуртулмасбыз [14.4], бар вә ләкин сизқә бирмәсмин тиди [16.18], дунийа хәли ахирәт хәлиғә мәңзәмәз [516.2];

«Нәһҗел-фәрадис»тә: ничәгә тәги ивдә олтурурсән бизләр йылқы қара қатынға чықармыз сывлар бар чимкәнләр чичәкләр бар анда ойнарбыз оқ атарбыз [353.17], аранлардин бәйғәт алсам әликләрини тутуп бәйғәт алурмән [26.10] һ.б.

«Хөсрәү вә Ширин»дә: не бир мәхрәм табар Ширингә ызғу [124.20], күнүл ансыз тиләмәз дәүләт вә таз [96.1], болур әрксиз бу күңлүм [88.7], ош айтурман вәли болса йер аулақ [37.18] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки»дә: сәни мақсудыңа илтүр көни йул [25v], китәр қәдриң ол дәм келип сөзләсәң улулар қатында йақамас қәлам [21v.6] һ.б.

Хәзерге-киләчәк заманның зат-сан белән төрләнеш парадигмасы теркәлгән.

I зат берлектә фигыль формасына *-мән* кушымчасы ялгана, сирәк *-м* варианты теркәлгән. Мисаллар: «Кыйссасел-әнбия»: йатурмән [9.6], шүкр қылурмән [17.18], тағәт қылурмән [17.14], бирмәсмән [16.18] һ.б.

I зат күплектә фигыль формасына *-мыз* кушымчасы ялгана, сөйләм теленә хас *-быз* вариантының активлашуы, «Хөсрәү вә Ширин», «Гөлестан бит-төрки», «Мәхәббәтнамә» текстында бердәнбер форма булуы, нормалашуы теркәлгән.

«Нәһҗел-фәрадис»та: *-мыз ~ -быз:* бирурмиз [58.9] ~ бирүрбиз [216.1], севермиз [435.16], атарбыз, ойнарбыз [353.17], чыгармыз [353.16] һ.б.;

II зат берлектә фигыль формасына *-сән* кушымчасы ялгана: «Кыйссасел-әнбия»дә: билүрсән [12.16]; «Нәһҗел-фәрадис»тә: айырсән [226.3], бирүрсән [8.12], тейүрсән [399.2], сәвәрсән [11.5] һ.б.; ХШ.: билүр сән [220.15], сурар сән [91.3], сөзләрсән [37.10], кизләрсән [38.10], көрәрсән [51.14] һ.б.; Мн.: әгәр дисәм сине Рүстәм йарарсын қылучың бирлә сафларны йарарсын һ.б.

II зат күплектә фигыль формасына *-сыз* кушымчасы ялгана: «Нәһҗел-фәрадис»: сакларсыз [199.7], коркарсыз [243.3], бәрүрсез [109.15];: торурсыз [Җж. 8.9] һ.б.

III зат берлек формасы әдәби истәлекләр телендә актив кулланылган: ривайатда кәлүр [КР. 14.5], намаз қылур [КР. 17.15], йунар [НФ. 171.13], тәгүрүр [НФ. 381.2], йурур [ХШ. 229.14], тамар [Мн. 72], алур [Гб.55v.10] һ.б.

III зат күплектә фигыль формасына *-лар* кушымчасы ялгана: қулурлар [КР. 13.6], алурлар [НФ. 44.11], йатурлар [Җж. А.15б, 3] һ.б.

Юклык формасы *-маз/-мәз, -мас/-мәс* кушымчалары ала. Мисаллар:

«Кыйссасел-әнбия»: *-маз/-мәз:* бу Кәсүр мәниң табуғымға йарамаз [8.11], бәз бу сүзгә бүтмәзмиз [6.12], сирәк *-мас:* ол йир кайу турур билмәсмин [6.13] һ.б.;

«Нәһҗел-фәрадис»тә: *-маз ~ -мас:* қылмазмәр [152.6] ~ кылмасмән [152.7], йығламаз мән [316.13], анд ичмәз [134.6], билмәсмән [259.4], сөзләмәссән [8.11], билмәз [171.13] һ.б.; Җж: болмаз [10.40], тынмаз [10.14, 10.42] һ.б.;

«Кискебаш китабы»нда: *-мас:* қазғу қоймас күзләримни уйқуға [68], тағ вә таш йетмәс [93] һ.б.

I зат берлектә *-ман/-мән:* мин сизни унутман [146], йавутман [146], етман [435]; баш көтүрмән [335], сендин йүс чәвүрмән [335] һ.б.; III зат берлектә *-мас, -мәс:* қалмас [98], йетмәс [117], теләмәс [354], болмас [371] һ.б.; Гб.: *-мас/-мәс:* келмәс [22v.10], йетәлмәс [37v.11] тута билмәс [94v.10] өлмәс [94v.11] һ.б.

*-йур/-йүр* кушымчалы фигыльнең Алтын Урда язма текстларында бары сөйләп торган моментта үтәлгән эш-хәлләрне белдергән мәгънәсе теркәлгән. *-йур/-йүр* кушымчалы фигыльләр чагыштырмача сирәк теркәлгән, барлык әсәрләр өчен хас түгел. Мисаллар: «Кыйссасел-әнбия»дә: имди бәзқә аталарымыз динини қудуб әдин дингә мү өндәйүрсән [6.11], сән бәзгә нә тийүрсән [12.12] һ.б. Бер җөмлә эчендә *-ар ~ -йу*р формаларының вариатив кулланылу очраклары теркәлгән: әй оғлум сәни түшүмдә буғузлайур көрәрмин [511.19], тиңиздин чықар ахшам оғурында кимни болса йийүр [17.12] һ.б.;

«Нәһҗел-фәрадис»та: бу қуйлар қайу йәрдә отлайурлар [293.12], бу кимниң қәбиләси турур инкән қайур йүрүйур ләр [50.10] һ.б.; Жҗ (бары 2 мисал): ким тиләйүрмән тирилгәй ош тәнин [23а.12], бир фәқир кәлди ихсан тиләйүр [17б.18];

«Хөсрәү вә Ширин»дә: йийүрмән заһмин [109v], кедик авунга киргәйму тийүрмән [39v]; сүчүг тил бирлә мини алдайурсән [109r] һ.б.

*-а/-ә* кушымчалы хикәя фигыль истәлекләр телендә хәзерге заман мәгънәләрен белдерү өчен кулланылган. «Кыйссаи Йосыф» текстында *-а* күрсәткечле фигыль мәгънә киңлеге белән аерылып тора, шулай да киләчәк заманны белдерү зур урын алып торуы ачыкланды. Алтын Урда чоры истәлекләрендә әлеге форма шактый сирәк теркәлгән, нигездә сөйләү моментында башкарылган процессны тәгъбир итә. Мисаллар: НФ.: әгәр син аны көрмәсәң ол сини шәксиз көрә турур [428.5], кәфер ләр күлүшү турурлар [12.8], сизләр ағыр чәрик бирлә бара турурсыз [23.15], Зөләйха сәниң нә зәхмәтиң бар ким күндин күн зәғиф булу турур сән [359.1], сатғын алып турум мән [180.1] һ.б.

«Кискебаш китабы» (барлыгы 11 сүзформа), «Гөлестан бит-төрки» текстларында *-а* формасы сөйләм моментыннан соң үтәләчәк эш-хәлләрне белдерә.

«Кискебаш китабы»нда: йә мән өләм йә девниң башын кесәм хақ ғинайат қылур ирсә мән басам [73, 74], бу сәғәт сәни йейәм [181], хәлә мән барам теди [177], уйур иркән бу девни қыла параә [160] һ.б.;

«Гөлестан бит-төрки»дә: сүзләмәк тиләбиз ничәким мүрк адәб исә шиғер [127v-11], йә иһаһи сән морадин бир аңа ким бу мискинни

доға бирлә аңа [178r-2], йақарлар ол кишини отқа йарын қойуп михнәт ичиндә китә йарын [132v-2] һ.б.

Хәзерге заман фигыль мәгънәсен *-а турур* (барлыгы 3 очрак), *-адур/-едур* (барлыгы 9 очрак) күрсәткечләре белән белдерелгән: ғатасын кесмейин бирә турур [3 r .7], еүдә йаһни бишә турур [74 r .9], өчүңни чүн хасед андан аладур [173.11], артурадур мал вә мөлкин [160r.2], бир йирдә дәгүл килип китәдүр көңлүң [72v.9] һ.б.

Алтын Урда чоры язма истәлекләре телендә *-р/-ар/-әр/-ур/-үр/-ыр/-ир* кушымчалы хәзерге-киләчәк заман актив кулланылган, тулы төрләнеш парадигмасы теркәлгән. Зат-сан формаларының кулланылышын күзәтү бердәм норма саклануын күрергә мөмкинлек бирә. Әдәби телгә сөйләм теленең йогынтысы, әдәби телдәге региональ үзенчәлекләр I зат күплек сан *-мыз ~ -быз* вариантларында күзәтелә. «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис» телендә ике форма да кулланылган, *-мыз* норма булып тора. «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхәббәтнамә», «Гөлестан бит-төрки» текстларында бары бер күрсәткеч *-быз* теркәлгән, «Җөмҗөмә солтан», «Кисекбаш китабы» текстында бөтенләй күзәтелми.

*-йур/-йүр* кушымчалы фигыльнең сирәк кулланылышы чагыла. *-а* формалы заманның III зат формасы сирәк «Җөмҗөмә солтан», «Кисекбаш китабы», «Хөсрәү вә Ширин» текстларында теркәлгән, бу форманың сөйләм теленнән керүен тәгъбир итә алабыз, «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә *-а турур* аналитик формасы кулланылган.

Киләчәк заман. Сөйләү моментыннан соң һичшиксез үтәләчәк эш-хәлләрне белдерү өчен Алтын Урда әдәби истәлекләр телендә *-ғай/-гәй, -ғусы, -ысар* аффикслы фигыльләр шактый еш кулланыла.

«Кыйссасел-әнбия»: а) *-ғай/-гәй,* б) *-ғусы турур* формалары кулланылган.

а) I зат берлек сан: қамуғ ғаибләрни кичүркәймин [515.15], аның арқасындин бир иләвеч идғәймин [518.3], мән бу қызларымда бирин сәңә бәркәймән [15.5]; 2 зат берлек сан: әй оғлум нәтәк сабур қылғайсән [512.6];

III зат берлек сан: йәкшәмбе күн ғазаб йитилкәй [15.17], ахыр заман пәйғамбәри Исмағил уруғындин болғай [513.18]; III зат күплек сан: кишиләр кәлиб асрамақға қулғайлар [10.7], ануң һошлуқында мөэминләр он айлық бирлә җан бәркәйләр [514.28] һ.б. И. Ильминский басмасында *-ғай* формасы семантикасында борынгы чыганакта күзәтелмәгән теләк мәгънәсе бирелә: һич ким қарындашыны сатмағай

[И. 183.5], өммәтләр бирлә җәмағәт намазын оқуғай [И. 409.11], йырақ йиргә илтиб саткай [И. 140.14], әй ана кәшки синдин бурун өлкәй ирдим тиб йығлады [И. 141.5].

Борынгы төрки әдәби традициянең саклануы турында әсәр телендә теркәлгән *ғусы* формасы сөйли: Самуд буғуны бу ташдин һаләк булғусы [13.4], Маули Тәғалә мәңа ни җаза биргүси [9.14], йарлық кәлди әй Ибраһим бу Исхақ атлығ оғлуңдин миң иләвеч булғусы [517.260] һ.б.

«Нәһҗел-фәрадис» телендә киләчәк заманның бер генә формасы теркәлгән, ул *-гай/-гәй* кушымчалары белән ясала һәм I төр зат кушымчалары алып төрләнә: бу түш изгү түш турур қызым Фатыйма әркәк оғлан тоғурғай [178.11], халаиқны изғай [131.4], суф тонлар кәдгәйләр [402.5], әгәр оғлум улуғайса ул сахрақа барғай тәқы ул бузағуны таләб қылғай тип әйтмис әрди [341.13], Тәңри тәғәлә мәни заиғ қылмағай [45.3], айға күнгә табынмағайлар [403.11], I зат берлектә: ачғаймән [149.5], ағырлағаймән [196.10], биргәймән [74.1]; I зат күплек сан болғаймыз [28.10], айғаймыз [187.4], биргәймиз [324.8]; II зат берлек сан: болғайсән [8.17], барғайсән [323.3], биргәйсән [356.14]; II зат күплек сан: айғайсыз [15.8], биргәйсиз [114.13]; III зат берлек сан: ачғай [149.7], алғай [352.17], биргәй [9.4]; III зат күплек сан: алғайлар [333.1], биргәйләр [116.17] һ.б.;

«Җөмҗөмә солтан» әсәрендә киләчәк заман *-ғай, -ысар* кушымчалары белән ясала: қылғай мән [61а.21], тыңлагай мән [16а.5], кәлгәйсән [18б.17], күргәйсән [18б.17], тирилгәй [23а.12], ишиткәй, билгәй [49.12]; тынлағаймән үз тилиндин хәлни [15.5], қарындашларыңы күргәйсән [18.17], ким арығсызлықдин үзимни йығаймән [47.15]; ким тиләйүрмән тирилгәй ош тәним ғибадәт қылғаймән қач йылтағы тәңри мәни ғафу қылғай [23а.12, 13]; *-ысар:* җан қуш учасар [16а.2], чөн бу ғаләм ғайақибәт йоқ болисар мундағылар һич бақи қалмайсәр [15а.1], хатими ол болисәр [49.21], анлардин җан алисәр [49.24].

«Кисекбаш» әсәрендә шулай ук *-ғай* кушымчалы фигыльләр актив кулланылган, *-ысар* бары тик ике мәртәбә генә кабатлана: сөзләгәйим бир хоп әҙгү дастан [1], сөзләгәймән хақ қылур ирсә йары [4], хақ йары қылса тилимкә сөзләгәй [15], Мустафа шәрх әйләгәй муминләр ешитип қалғайлар таңа [16, 17]; *-ысар*: Ғәли әйтүр чара йоқ барысарым башымға йазмушымны көрүсәрәм [82, 83].

Киләчәк заманның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә *-р, -ғай (-ға), -ғу, -ысар* формалары теркәлгән.

*-ғай* (385 мәртәбә теркәлгән):

I зат берлектә: хәбәр қылғаймән [30.2], ойағлық табмағаймән [90.9], үлтүргәймән елгиндин үзүмни [110.5], доға бирлә улашу мәдәд қылғайман [90.3];

II зат берлектә: рәхимсиз болғайсән [168.11], қутулғайсан бу қадғудин [229.4];

III зат берлектә: ким оқуса билгәй [233.11], таш үзрә мендин артуқ нәқш қылғай [121.8], қалқан тутғай [90.1], сүзүм алғай [66.9], тил қалғай әбсәм [62.10], исиң биткәй [98.12]; әгәр тапмасам һич чара хәбәр қылғаймән шаһы зиһандар [26], йарутғай бу қара күңлүмни ол ай [194], уминч бар ким сәғәдәт күни тоғғай бу қул қолы шаһым бойнында болғай [194], урушда душманыңа таш атғай [87], кирәк ким сүз йириндә сөзләтилгәй [116], ишитгәймән ни ким сөзләсә сөзин [161] һ.б.

*-ға* варианты 67 мәртәбә кабатлана.

I зат берлектә *-мән* – 23 тапкыр, *-м* 10 мәртәбә теркәлгән: бергәмән [29.11], барғаман [76.6], табғамән [24.10], қылғамән [132.8, 136.4, 171.5], йымғамән [134.8], сүргәм [129.4], йегәм [101.17], салғам [113.14], бергәм [84.12], үзгәм [151.10], тамам йағсыз чырағ тег тартғамән җан [184.20], қылғам [118.8, 93.9, 44.14]; чықарыб бу күнүлни иткә салғам [113.14], айытты тилгәмән таш бирлә башын [129.6], бергәм сәңа җан [89.12] һ.б.;

I зат күплектә: йатғабыз [57.16];

II зат берлектә *-сән:* қылғасән [138.4], табғасән [24.5], қачғасән [212.12] һ.б.;

II зат күплектә: болғасыз [11.10, 52.61], алғасыз [111.10];

III зат берлектә: қылға [197.21, 190.15], күрүб бир бириңиз не болға сыз шад [111.10], болға [141.19, 125.21, 187.13], чыгға [24.9], табға [23.4], йар илгә киргә [13.10], мени мат қылға тейү шаһ ойнаб [46.8], һ.б.

III зат күплек формасы очрамый.

*-ысар* кушымчалы фигыль «Хөсрәү вә Ширин» телендә бары тик ике мәртәбә кабатлана: ош түн барды бу күн қалмайысар [194v], ким уш биз тег бизе ким йығ байысар [225].

«Мәхәббәтнамә» телендә киләчәк заман мәгънәсен белдерү өчен *-гай/-гәй* кушымчалы фигыльләрнең III зат берлек саны кулланылган: качан үлсәм қәдрим билүргәй бу йолга түшсә Әфлатун тилүргәй [281]; синең атың ишеткәч, йерләр өпкәй [70], уҗмахда булгай [349] һ.б.

«Гөлестан бит-төрки» текстында шулай ук киләчәк заман *-гай/-гәй* кушымчалы фигыльләр белән белдерелгән, 1 төр зат кушымчалары

алып төрләнгән: пәри күрсә сени, миндек тилүргәй [116], көнүлниң қаны қайнаб барча ташқай [119], таң атқай [149]; лалә солғай [349] һ.б.

I зат берлек сан: *-мән:* алғаймән [131v.1] айтқай мән [59p.11] кит киймән [25v.1];

I зат күплектә: *-быз/-биз:* болғай быз [42v.7], қылғайбыз [77v.11], кит кейбиз [103v.11];

II зат берлектә *-сән:* алғайсән [53.5] тапқайсән [175v.4], билгәйсән [119v.12];

II зат күплектә: *-сыз/-сиз:* ишиткәй сиз [109.11], тутқайсыз [67r5]; III зат берлектә: келгәй [18r.5] йегәй [31r.8], китгәй [38v.6], қалғай [30v.10], башлағай [133r.1];

III зат күплектә *-лар:* алғайлар [171r.10], айтқайлар [25v.3] һ.б. Юклыкта: көрмәгәйсән [19v.9], азар қылмағайсән [20v.3], бирмәгәйсән [40v.7] һ.б. *-га* формалы киләчәк заман II зат берлек санда кулланылган: иксәң хайыр урлуқыны бичкәсән күзигә ни қойсаң аны ичкәсән [5r.23], ни қәдар қылғасән бу золм илгә [20r.10], җан үә көңүлни ни билән алғасән [117v.67] һ.б.

Киләчәк заман күрсәткече *-ысар* 10 мәртәбә кулланылган: бу җәвап вә җәфа ничә болусар сендин хақ аның үчүн алусар [148r.8,9], қанда болусар дост кәрәмдин мәхрум [3r.9] болусар қуруйир [142v.13] «высохнет земля», миннәт көтүп тирилгән ир хор өлисәр [106r.4] һ.б.

Алтын Урда чоры язма истәлекләре телендә киләчәк заман күрсәткече *-гай* формасының норма булуы билгеләнә. Шул ук вакытта *-гу, -ысар, -гучы* традицион формаларның спорадик. ягъни сирәгрәк булса да «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Гөлестан бит-төрки», «Җөмҗөмә солтан» текстларында кулланылышы күзәтелә.

*Теләк фигыль.* Теләк наклонениесе I зат берлек һәм күплектә теркәлгән, күпчелек очракта *-айын, -әйен, -галың, -алым, -айым, -гам* вариантлары күплек формасы *-әлүм, -алум, -алуң, -алым, -әлең, -алың, -гәлиң, -алық* вариантлары белән белдерелә, *-айым, -әйем, -и* формасы аз санда күзәтелде. Мисаллар:

«Кыйссасел-әнбия»: I зат берлек сан:емди Исмәғилни анда елтәйин [510-6]; мәңа дәстүр бергил барайын ғаләм ичиндә бирәӡгү кул тиләйин [17-8]; мәңа инанмас ерсәң кәлгил сәңа көркүзәйин [10-2]; I зат күплек сан: *-алың, -әлиң:* қамуғлары кеңәштиләр Салихны өзүмиздин үмидсиз қылалың [12-10]; әйдиләр бир нәрсә қылалың [12-12]; биз өз Тәңримиздин қылалың [12-18]; қайузы тирикрәк бәрүр ирмиш

күрәлиң [12-18]; Салихны өлтүрәлиң бәзгә ғазаб тикмәсдин бурун [15-18]; сән доға қылғыл биз бәрәлиң [13-8].

«Кыйссасел-әнбия»нең соңгы күчермәләрендә *-галың, -алым, -айым, -гам* вариантлары булуы тәгъбир ителә. Мисаллар: имди муңа ни хәйлә қылайым [12а]; мәним қурбаным нә турур нә ни қурбан қылайым [32б]; Рәхимәгә йүз ағач урғам [180а]; кәчүб бу йергә киләлим [31б]; имди сәниң сөзүңдин чықмалың [133б] [Шукуров, 1974, с. 22, 28].

«Нәһҗел-Фәрадис» әсәрендә теләкне белдерү өчен берлек санда *-айым, -айын* формалары кулланылган: мән бурун кирәйин бақайын адамини азарлаған җанварлар болмасун [21-3]; биз ул тағәмны қылын кәлтүрлиң [25-5]; Йа Абу Бәкр бу әсирләрни нәтәк қылалың туралың [115-1] һ.б.

Теләк фигыльнең күплеге *-гәлиң, -алым, -алық, -алың* вариантларында теркәлгән: бу оғланны оғул тигәлиң оғлумуз болсун [359-12]; хатунларығызны үндәгәлиң [88-3]; бу Йусуфны бурун хақ үлтүрәлим йә тәқы йырақ йирдә бырақалым [355]; биз тәқы җүмлә йаранларқа иғлам қылалық бир қата хамла қылып һәлақ қылалың [40-7].

«Җөмҗөмә солтан» әсәрендә теләк фигыль формалары сирәк очрый: тыңла имди хәлим әйтим сиңа [42]; тыңла сән күрдүкәм чәрх идәйим [46].

«Кисекбаш китабы»нда: йа Ғәли мән барайын зулфиқәр илә дев җигәрин йарайын қутқарайын дев илидин ғәуратны [72]; йыққайын Мәккә Мәдинә шәһрини [184]; күплектә: үстүмиздә хақны хәзир күрәлим Мустафаның җәмәғәтинә ералым [4]; ол Ғәлиниң ерликини саналым [11]; назым бирлә хоп шәрхин қылалым [12]; дурушалым түн үә күн Алла илә [2], биз неталым ду қуйуғда биз нә хәйлә қылалым [233] һ.б.

Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә *-айым, -айын,-гайн, -гам, -ай* (берлектә), *-алың, -алым, -галым, -галың* (күплектә) теләкне белдерү өчен кулланыла. *-айым* варианты норма булып тора: бир ики һафта мән мунда болайын нитәк кечмиш аның халын биләйин ишитәйин бир татлы сүзүң [29v-6, 7]; ишитәйин бир татлы сүзүң [167v-8]; җамалыңдин үлүшлүк һәм болайын [198v-18]; адақың топрақын сүрмә қылайын / синиң хошнудлуқыңны оқ биләйин [196r] һ.б.; 4 мисалда *-айын* варианты очрады: барайын мән тип үзи оқ йолға түшти [33r]; айайын мән қулақ тут йахшы тыңла [3624]; тиләйин мән үзүмни отдин азад идим [4403]. *-айым* варианты 12 сүзформада теркәлгән: қылайым тапуғ ата чанны қурбан [52r]; йазуқум бар исә айсун билейин [161]; барайым [95]; турайым [170]; нитәк сүз қабығындин мән ачайым

[106]; -ғайын, -ғайым варианты 7 мәртәбә очрый: мини қой үз ишимкә йығлағайын [112]; йимүм қазғу болды хош йигәйим [112]; олтуруп түз сүзләгәйин [110]; түз сүзүнни кизләгәйин [110] һ.б.

Теләк фигыльнең I зат күплеген белдерү өчен -алың, -әлиң, -алым, -ғәлим, -ғәлиң вариантлары теркәлгән: күрүшәлиң бары бир дәм үзүмиз [100v-2]; табуғында баралың ағурлаб үз йерингә йеткүрүлиң [101r-26]; кел имди бир кечә һош олтуралың ойағлық мәҗлисин бу түн қуралың [28r-24]; килсүн күрәлиң [124]; -алым (3 мәртәбә): үзүмүздин чәүрәлим йүз [83 v]; ызалым илчи килтүрсүнләр [1134]; қылалым барчамыз аны ғиззәт [63 v]; аш йигәлим [29 v]; ғалың: шах айды биз ики топ ойнағалуң қайумыз йахшы ойнар бир бақалың [35 v].

«Мәхәббәтнамә» әсәрендә теләк мәгънәсе *-айын* (берлектә), -ғайын (күплектә) кушымчалары белән белдерелгән: күчим йетмишчә күп һидмәт қылайын җиһанға едгү атыңны йәйәйын [39]; җиһлайын ики бабын парсы [62]; сәнәдин үзгә нәвә атлас тоқуйын / қыш ортада бахариат оқуйын [92] һ.б.; бурун әлқысса бәк мәдхин айайын ош андин соңра намә башлағайын [63]; салайын үзүмиүзгә адйара / күңүлни бағлағайын үзгә йара [365]. Сирәк очрый: сурахи толса қоп ағзын ачалың / бүгүн мәйханәдә йармақ сачалың [265]; ичәлиң бадани гүлләр солысар [381]; бизниң бәк йадыға ғашрәт қылалы [89].

Язучы «Гөлестан бит-төрки» әсәрендә теләкне белдерү өчен *-айым, -әйим, -ғайым/-ғайим* (берлектә), *-алым/-әлим* (күплектә) вариантларыннан файдаланган. Мисаллар: қулақ тутсаң җаwаб айтайым [22v-12] ничә йитсә күчүм көңлүң алайым / тахаммүл җаwрииә дайим қылайым [133r-67]; кимгә дигәйим ничүк қылайым билмен [55r-11]; Қөрәнне мин оқығайым [137v-4], йатасы йер дәгил тур китәлим [136v-12]; таң биләтабиб изделим [263r-3]; мәлик айтты барып анда түшәлим [90v-13] һ.б.

Күзәтүләрдән күренгәнчә, Алтын Урда чоры истәлекләрендә теләк наклонениесе күп төрле кушымчалар белән белдерелгән.

| Ядкәр | I зат берлек сан | | | | I зат күплек сан | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | -айын | -айым | -ғайын | -им | -алың | -алым | -ғалук | -ғалум | -алы | -ғалың |
| «Кыйссасел-әнбия» | О | ◙ | | | О | ◙ | | | | 1 |
| «Нәһҗел-фәрадис» | О | ◙ | | | О | ◙ | ◙ | | | |
| «Җөмҗөмә солтан» | | О | | 1 | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Кисекбаш китабы» | О | | | | | | | | | |
| «Хөсрәү вә Ширин» | О | ◙ | ◙ | | О | ◙ | | ◙ | | ◙ |
| «Мәхәббәтнамә» | О | | ◙ | | О | | | | | |
| «Гөлестан бит-төрки» | | О | ◙ | | О | | | | ◙ | |

О – норма
◙ – вариативлык

### 2.6.2. Затланышсыз фигыль формалары

*Сыйфат фигыльләр*. Әсәрләр телендә сыйфат фигыльнең төрки әдәби телдә билгеле барлык вариантлары урын алган: *-ган/-гән, -мыш/-меш, -ан/-ән, -дык/-дек, -ар/-әр, -ур/-үр, -ғучы, -ғу, -дачы, -асы.* Истәлекләр телендә – *-ган/-гән, -мыш/-меш, -ар/-әр* кушымчалы фигыльләр өстенлек иткән, традициион формалардан *-ан/-ән, -дык/-дек, -ғучы, -ғу, -дачы* варианты аерым мисалларда гына кулланылган. Бу чор әдәби телендә *-асы* кушымчалы киләчәк заман формасының әдәби телгә үтеп керүе теркәлгән.

Үткән заман сыйфат фигыльләрнең доминанта күрсәткече булып *-ган/-гән, -мыш/-меш* формалары килә.

«Кыйссасел-әнбия»: *-мыш/-миш, -муш/-мүш:* бир инкән чықты олар тиләмиш тик [13-10], Җабраил бишарәт бармушда йәти күндин соң Сара сонукында Исхақ билкүрди [519-3]; Нух куҙуну туфанда һәлак болмышда киҙин Нухның үч оғлы қалды [6-15]; Ибраһим түш көрмишдә әйдиләр [509-19], сәвүнмишдә Әйҙигә шүкр қылды [518-1], Җабраил Лут иләвеч буҙуну һәлак қылғалы кәлмишдә Ибраһим иләвечқә Сарадун Исхақ атлығ оғлуң болур тиб бәшарәт бәрди [517-12] һ.б.

*-гән, -кән:* ғәләм ичиндә иң илик үз кәҙдүркән Хәндағ бин Гөмәр [10-19], мәндин әшин тәңрини бирләгән ким ирсә йоқ ирди [17-13]; қачан қулдашларымни мәктүбдә йығылыб олтурғанларда көрсәң… [512-21] һ.б.

«Нәһҗел-Фарадис» телендә үткән заманның *-ган, -мыш* вариантлары актив кулланылган: хатунларны тул қылған уғланларны эксүз қылған адәмләрни хараб қылған мәлик Алмут [88-16]; залимләр қазыған арықдин суварылған үзүм турур [297-12]; буйурған ишләрини қылмадым йаған ишләриндин йуғылмадым [147-10]; улуғумуз сүзләгән сүз [256]; кичкән түн сәждәгә бардым [426] һ.б.

*-мыш:* сән маңа үрүлмүш сачыңны биргил [332-5]; қызмыш ташлар күйдүрүр [315-17], қызмиш тәмүр [235-15]; Хақ тәғаләниң фәрманы бирлә бина қылынмыш қағбәгә зийарат қылыңлар [39-1]; алтары битилмиш ташлар [43-13]; урулмуш игинниң ушақ йапрақы тик һәлак қылды [43-14] һ.б.

Үткән заман сыйфат фигыль күп төрле функцияләрдә килә, исемләшә: ғилемни билмәгәнләргә үгрәтсә аның саwабы тәқы дәрәҗәси олуғ турур [230-15]; олтурғанлардин бири балта алды [303-13], бу хаҗ қылдурғанғың ул бир тулғақ зәхмәтинә җәза әрмәс [286-2]; танаул қылмағаныны ул зәғифәгә айды [297-5]; ул кирмишимдә үрү қобты [287-10]; сиңа тәрбит қылмышта йаман қылықлығ әрмәз ирди [285-16]; тәкмә бир сурамышыңда лотф вә кәрәм бирлә җаваб әйтүр ирдим [288-7]; вәғдә қылмышыңа вафа қылғыл [153-2]. Тартым кушымчасы сыйфат фигыль күрсәткеченә ялгану очраклары теркәлгән: моңа әмгәнип қылғаным ғилемләрдин миңа һич манафағаты тәкмәди [231-16]; тиләгәни алтунларны бирди [252-1].

Җөмләнең хәбәре булып килә: мундағ кишиләр күрмишим йоқ [103-4]; өпмишим йоқ [291-2].

*-дуқ/-дук* формасының кулланылышы аерым мисаллар белән чикләнә: ул му мингә санмадуқ йүндин рузаны тәгәргәй [188]; сәңә нә мәғлум болды аның уҗтмахлығ әрдүғи [239-7].

«Җөмҗөмә солтан» әсәрендә үткән заманның *-ган, -мыш* вариантлары актив кулланылган: үстүнә мәнгән [16б-10]; тәңри бергән ризық [24а-1]; қылған ишләр [8-12]; кичкән ғөмремдә [7-21]; ол бина қылған улуғ дәргаһлар [39-10]; қан қуйулмыш таҗ [18а-20]; черемеш тән [23б-2]; бақты йазмыш әлиндә ики хат [41-12]; *-ан* формасы сирәк: сорайан сүзүн [3-3]; исемләшә: қылғаным ишләр [12-23]; җиһан бақыйдур тигәнләр қаны [1-1]; кирәнләр [3-36]; күрәнләр [3-35].

«Кисекбаш»та үткән заманның *-мыш* формасы өстенлек итә – а) атрибутив позициядә килә: Ғәли китәр ол кесилмиш баш илә [87]; б) исемләшә: башымға йазмышымны күрүсәрим [82]; күрүр ирдим башқа нә йазмыш келә [62]; в) исем фигыль функциясендә: етмишин һәм билмәди [200]; *-ган:* сүзләғәним бир хош дастан күңүлләр шад қылған дастан [5-6].

«Хөсрәү вә Ширин» телендә үткән заманның *-ган, -мыш* вариантлары актив кулланылышка ия: *-ган* формасы 172 мәртәбә, *-мыш* – 37 мәртәбә кабатлана. Үткән заман сыйфат фигыль күп төрле функцияләрдә атрибутив позициядә килә, исемләшә: күргән түши [212-12];

билгән кишидән [56]; Ширин үзи олтурған чадырдан чықып [198]; үзи килгән йирин соқынды [304] һ.б.; *-мыш:* қылымныш әдгүлүкдин аты қалды [149-10]; арға түшмиш аһы тегмән [196-26]; унутма қылғануң ишләрни [87]; Ширин Фарһадны… күрмәккә барғаны [132]; ириклик қылғанымқа бақма [90-18]; шаһдин үзин кизләгәнин [93], қой олтурма бу боз олтурмышыңны [176-5]; Хөсрәү Ширингә үфкүләнүб китмишдин соң Ширин Хөсрәү фирақындин зор калнышы [96-15].

*-дук* варианты исем фигыль функциясендә килә: не битүргән хәбәрлег бердүкиндин не йыған җаһид етиб мал тирдүкиндин [16-6].

«Мәхәббәтнамә» әсәрендә: ай сүзи йалған җафакәр [135]; сиз үлтүргән киши үлгәйму һәргиз [282]; вафа қылған кишиләргә вафа, қыл [107]; сени күргән үзендин йат болар [160]; хыйалың күздә учқанын билүрмән [351]; ашақ йелдин сениң йелгәндә атың [294]. *-ан:* шахин шах Җанибәк ханға йетәнсиз [293]; *-мыш:* ачықмыш бүри қойға кирү йаңлыш [76].

«Гөлестан бит-төрки» әсәрендә үткән заманның *-ган, -мыш* вариантлары актив кулланылган:

*-ган/-гән* формасы атрибутив позициядә килә: кигән тонума [110r-12]; ели айагы кесилгән ким әрсә [93r-1]; җиһан күргән ески киши бар иди [10v2-5]; башындан кечкән хәлләрни [22v]; йүк кәтүргән ешәк йахшырак ол арсландан ким адамини йыртқай [31r-10]; урушуп таш аткан ер билән [35r-2], насихат тутмаған гафил ким әрсә [28r-13] һ.б.

Исемләшә: әгин золым урлуқын хайыр истәгәнләр [19r-12]; махдум болур һәмишә фәрман тутқан, мәһрум қалур һәмишә ысған күткән [37r-4]; сәниң елиңдән болғаны йахшырақ [36r-9] һ.б.

Исем фигыль функциясендә килә: ишиткәниң йоқ му муны [18v-4]; икинчи батып чыкқанында сачында тутып кеми үстинә кәтүрдиләр [17v-8]; сән дағы сүзләгил күргәниңдән wә ишиткәниңдән [92v-13]; Мәккәни зыйарат қылып келгәнимдә [27v-5]; сән айтқаның киби болду [27v-7]; һақиқәт дустың йарың дур ол ким қолуң тутса айақдан түшкәниңдә [27r-3] һ.б.

*-мыш* кушымчалы фигыль азрак кулланылыш тапкан: қурмыш буғдай [176r], сусамыш ир, сүнәк дер җанwәр ринҗитмиши йоқ [23v-10].

*-дуқ/-дук* формасы текстта аерым мисаллар белән чикләнгән: Башымдин китмәди һәргиз сәнүң илә ичтүгүм [184r-3], сәwдүгүм бән адамилар җаныдур [179r].

*-ыр/-ер, -ар/-әр* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыль. Хәзерге барлык төрки телләрдә диярлек кулланылышта булган *-ыр/-ер,*

-р кушымчалы сыйфат фигыль килеп чыгышы буенча иң борынгы формалардан санала, борынгы Орхон-Енисей язмаларында ук урын алган. Тикшеренүчеләр шулай ук әлеге сыйфат фигыльнең беркадәр соңрак чорларга, ягъни XI–XIV йөзләргә караган язма истәлекләрдә дә актив кулланылышын билгелиләр.

*-ар/-әр, -ур/-үр* кушымчасы сыйфат фигыль атрибутив позициядә хәзерге-киләчәк заман төсмере белән барлык әсәрләрдә кулланыла, шулай ук субстанцияләшә:

«Кыйссасел-әнбия»: тәвәниң килүр йолында пусуб олтурдылар [15-6], ғыйлем үгрәнүр қулдашларымны күрсәң [512-21]. *-ғу* кушымчалы фигыль тиешлек төсмере белән азрак кулланылыш тапкан: йалғуз уруш қылғу йарағым йоқ [15-13].

«Нәһҗел-Фәрадис»: күрәр күзүң күрмәс болғай тутар илкиң тутмас болғай йүрүр азағың ярәмәс болғай сүзләр тилиң сүзләмәс болғай [180-16]; барур вақыты йақуды [84-12]; сүт әмәр уғлан [362-3]; келүр йыл зийарат қылғайсыз [391-17]; йулда барурда сахрада Гамирға сатғаштылар [146-17]; учуп кәлүрдә сән нә әйдиң [392-7] һ.б.

Традицион әдәби тел формаларыннан *-ғу, -ғасы, -ғасы турур, -ғучы* вариантлары сирәк кулланылыш тапкан: сизин кәчмиш йазуқларың тәқы кәлгү йазықларыңызны йарлықап турур [314-15]; Хақ тәғәләқа сатғашғу вақыт болды [83-10]; үркәгү йерләрини учтмах қылғыл [318-11]; ойнағучы [183-16] һ.б.

Традицион формалардан *-дачы* аерым мисалларда сакланган: Хақ тәғәлә пәйғәмбәрнүң кәлмиш тәқы кәлдәчи йазуқыны йарлықамышдин суң [84-1]; Тәңри тәғәлә пәйғамбар ғаләйһиссәламқа сана айтур тақы қылынмыш қылдачы заллатларыны йарлықар [4-2]; тәңрининң үзрәндәчи қулы атам [93-5].

«Җөмҗөмә солтан» әсәрендә хәзерге һәм киләчәк заман күрсәткечләреннән *-р, -ғучы, -асы* вариантлары теркәлгән. *-үр:* әйтүр сүзүңни [41-28]; *-гучы:* ечинә киргүчиләр җәннәт дир иди [16б-9]; йалған сүзләгүчиләр [20а-14]; *-асы:* бәр бирси ирмеш бир иқлим ийаси авлан түрлүк ирмеш кыйасы һәм йиәси [11-27].

«Кисекбаш китабы»нда хәзерге-киләчәк заман сыйфат фигыльләрдән *-р* варианты гына теркәлгән: уйур девни үлтүрмәк ерлик дәгил [163]; имди сән уйур девни үлтүрерсин [166].

«Хөсрәү вә Ширин» текстында хәзерге һәм киләчәк заман күрсәткечләреннән *-р, -ғучы, -ғу, -асы* вариантлары теркәлгән.

*-р:* түшәр йергә бурунрақ ийдиләр қуш [75-18], йана бу расулның сәвәр ишләри [11-20], түшәр йер [75-18]; йығлар күзләримиз [79-8]; кишидән қорқмаз емгәнмәз киши ол [126-19]; сагылды ирсә сув сүнди йанар күз [34r]; саңа миндин йарар иш килмәз [79r]; ичәрдә ол шараби [9r]; оқуғлы оқурда оңарур аны [115r].

*-ғу* формасы 7 мәртәбә теркәлгән, сыйфат фигыль күп төрле функцияләрдә килә: а) атрибутив: йоқ учғу йарағум [95-17]; йеттиләр ав авлағу йергә [73-5]; йетип ики чәриг урушғу йиргә [91-20]; йоқ ерди анда бир луқма йегү аш [59-18] һ.б.; б) исемләшә: усал турғучылар күйүкдә қалды [106-45]; қамуғ йинчкә лақыб түз атғучылар [80-9] һ.б.; в) исем фигыль функциясендә: қамуғ ғаләм йүзүн күргүгә мухтаж [6r-4]; шәфәғәт қылғуға йығды улуғлар [10r-8]; ничәләр ким бишүрди йигүгә [98r-1].

*-ғучы:* сүз айғучы ер [30-14]; ол суратны нәқш етгүчи ул мән; ошбу күк атағучы йер [74-17]; қану ол арслан үлтүргүчи Парвиз [226-12]; өлүм килгүсиңә үңдин үлүп қой [31r]; баһасын алғучы һаддынча қылды [147-1]. Бары ике мисалда *-учы:* ирлаучы табғасән бир жанға рахат [24-5], бина қылғучыны үндәтти [53-10].

«Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә үк хәзерге татар теленә хас *-асы* киләчәк заман сыйфат фигыль кушымчасы теркәлгән: ким ол дивана ергә қыласы / не чара бирлә андин қуртуласы [124в], таңқа нә бакасы [194r].

«Мәхәббәтнамә» текстында киләчәк заман сыйфат фигыль бик сирәк кулланылган: чәчәксән бән дә сайрар булбулуңдур.

«Гөлестан бит-төрки» әсәрендә киләчәк заман сыйфат фигыль кушымчаларыннан *-ар, -ур, -асы, -ғу* вариантлары теркәлгән. *-әр, -ур* кушымчалы сыйфат фигыль а) атрибутив һәм ә) исем фигыль мәгънәсендә кулланылган: а) ай оғлум мән саңа китәр wақтын айтмадыммы [104р-7], тәңридән үзгә сығынур йерим қалмады [33r-8]; учар қушны ақар суwны тыйғай [98r11]; күңүл бирмә күнүл бирмәс кишигә [78r]; үпәрдә нәгәһ ойнаб тиш батырды [254v].

*-асы:* кәлүси михнәт йәшбиши [142v]; нә йатурсән йатасы йер дәгүл тур кәтәлим [136r-12].

*-қучы/-ғучы:* әй оқ атқучы йахшы сақышлар илк ат [169v]; қашан жан алғышы душман әришсә [95r].

Алтын Урда чоры истәлекләре телендә сыйфат фигыльнең төрки әдәби телдә билгеле барлык вариантлары урын алган: *-ған/-гән, -мыш/-меш, -ан/ -ән, -дык/-дек, -ар/-әр, -ур/-үр, -ғучы, -ғу, -дачы, -асы.*

Истәлекләр телендә *-ған/-гән, -мыш/-меш, -ар/-әр* кушымчалы фигыльләр өстенлек иткән, традицион формалардан *-ан/-ән, -дык/-дек, -ғучы, -ғу, -дачы* варианты аерым мисалларда гына кулланылган. Бу чор әдәби телендә *-асы* кушымчалы киләчәк заман формасының әдәби телгә үтеп керүе теркәлгән.

*Хәл фигыльләр.* Хәл фигыль – фигыль һәм рәвеш билгеләренә ия булган затланышсыз фигыль формасы. Алтын Урда чоры әдәби истәлекләр телендә теркәлгән хәл фигыльләр *-а/-ә, -у/-ү, -ып/-еп, -уб/-үб, -убән, -у/-ү, -йу/-йү,* сирәгрәк *-ун/-үн, -анчә/-әнчә, -ғалы/-гәле, -ғыча, -ғынча* формаларында килә.

«Кыйссасел-әнбия» текстында *-а/-ә, -у/-ү, -ып/-еп, -ғалы/-гәле, -ғыча, -ғынча* хәл фигыль формалары теркәлгән.

1. *-у/-ү, -йу/-йү, -а/-ә* кушымчалы хәл фигыльләр «Кыйссасел-әнбия» текстында иң актив кулланылган, төп фигыль белән бер үк вакытта булган эш-хәлләрне белдерә: ол көләгә тиңләйү Кәғбә бәнә қулғул [515.8], таш бәрлә қамуғыны ора һаләк қылды [16.6], иңрәйү көз йәши көңүл көйнүки бәрлә Исмәғилни күндүрү чықты [510.16]; бычақны ташға чалды тәқы йығлайу ағаз қылды [511.18], қой алу килкәймиз [510.18].

*-у/-ү, -йу/-йү, -а/-ә* кушымчалы хәл фигыльләр аналитик фигыльләр составында да кулланыла: Исмәғил таба килди вәсвәсә қылу башлады [511.14], таш иңрәйүбашлады [13.9], бүтәси бәрлән қобты отлайу башлады [13.10] һ.б.

2. *-ып/ -еп, -п, -уб/-үб* кушымчалы хәл фигыль күбрәк үзе ачыклаган төп фигыль белән а) бер үк вакытта булган, ә) төп фигыльдән алда булган эш-хәлләрне белдерә. Мисаллар: а) Мөүләгә шөкр қылыб тағәт қылур мән [17.4], бу хатун талифә болды йүгериб чарлайур ирди [8.20]; Салихны бизгә күркүзә бириң [16.16]; ә): андин қорқуб башым ақарды [9.14]; аталарымыз динини қуҙуб адын динғә мү үндәйүрсин [6.11]; ол евдин чықыб сөзләштиләр [7.12]; б) үтәлү рәвешен белдерә: барча боҙун аны таңлаб көрдиләр [5.10], бүтәси иңрәб қайтты [5.13], бир йылан килди ол йирдә қуврулуб йатты [515.10].

3. *-ғуча:* оларға таб булғуча қамуғ ботларға табынур ирдиләр [6.4],бәз бу тәвәни өлтүрмәкинчә мундин қуртулмасбыз [514.4].

4. *-гәли/-кәли:* мәликкә сәлам биргәли олтурур ирди [11.3], ол оғланнар аталары Салих пәйғамбәрни өлтүркәли оғрадылар [14.8] һ.б.

«Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә *-п, -ып/-ип, -уп/-үп* кушымчалы хәл фигыль актив кулланылышка ия: Йусуф пәйғамбәр қуаға йәбшүнүб

қузуғдин чықты [112.12]; оғлу тоныны кизип жумға намазына барды [106.2]; сизиң үчүн қазғуруп йығлармән [28.3].

*-у/-ү, -йу/-йү, -а/-ә* кушымчалы хәл фигыльләр: ғәламни гизә йүриғил [262-11]; тойа тәғам йимәдим [326-10]; қуш уча кәлди [288-2]; уфтану әйди [113-5]; тәмүрни чықарды отлар сачрайу [237-11]; сүзни қуану аймасман [36-7].

*-у/-ү, -йу/-йү, -а/-ә* кушымчалы хәл фигыльләр аналитик фигыльләр составында да кулланыла: бару башлады [354]; йыглайу башлады [358]; чыға турур [242]; йаратып турур [112]; бақа билмәгән [361]; қылу билмәгәй [229-7] һ.б.

*-гынча:* мин барғынча ул күвәчкә һич ким әрсә сүмчш қатмасун [28]; бир йердин кичик бала әркән учса қарынғынча [260-63]; тамуғ ғазабындин кәрәгинчә қурқар болса [235-2]; күнлүм тилагинчә тәрбит қылмаз [286].

*-галы:* Кағбәгә зийарат қылғалы бардым [88-1].

Юклыгы: атам амамқа сүтдин қандурмадин уғланларымқа бирмәс әрдим [293-8]; адами қәнәғәт қылмадин читләргә хидмәт қылса [302-8]; намазны қуҙур мақға шариғат изиләри рүхсәт бир мәдин турурлар [241-1].

«Җөмҗөмә солтан» текстында *-ып, -убан, -а, -у, -гач, -гунча* вариантлы хәл фигыльләр теркәлгән. *-п, -ып/-ип, -уп/-үп* кушымчалы хәл фигыль актив кулланылышка ия (32 мәртәбә теркәлгән): йатдылар бир парә бүзгә чулганып [39]; күзин күккә тикәп [41]; Ғәйсә пәйғамбәрә хәйран ичиндә қалып [16-3]; ким сатып алмыш ирди йармақ берип [44]; барып ол сув йақасында отрып [41]; ғибрәт алып хайран ечрә қалды аңа [41]. Соңгы җөмлә «Хөсрәү вә Ширин» текстында да очрый, язучылыр бер-берсееӊ әсәрен укыган дигән фикеребезне раслый: замана ишләриндин гибрәт алды болуб ғаҗиз таңзуб ичрә қалды [32б9].

Борынгы төрки әдәби текстларда теркәлгән *-убан* варианты 3 мәртәбә кабатлана: тахтемқа күтәрубән мәндүрдиләр [47]; қорқа имайубән суал қылдым [49]...

*-ганча, -канча:* күчүң йиткүнчә хәйер итмәк керәк [40-4]; ким болып солтан болғунча [22б-6]; күз тикәнчә [17б-11].

«Кисекбаш китабы»нда *-ып, -убан, -а, -у, -гунча* вариантлы хәл фигыльләр теркәлгән.

*-п, -ып/-ип, -уп/-үп* кушымчалы хәл фигыль актив кулланылышка ия: муэминләр ешитип қалғайлар таңа [17]; айтип вәргил бермәсүн

зәхмәт мәңә [42]; қулақ тотуп таңлар ирдиләр сүзин [22]; тағ [ы] тас йетмәс йумарланып китәр [93]; сени мунда ким берип ерди мәңә [178]; пәйғамбәр аны куруп қорқты жаны [33].

*-а/-ә, -у/-ү:* тура келди тәңрининң арсланы Ғәли [34]; қайу дев алды хатунны айра [104]; бир дәм олтурды Ғәли ақлын тирә [124]; йығлайу кирди торди күз йәшин [24]; чақрушдылар йа Ғәли ким дад тейү дев илиндин бер бизгә мудәд тейү [142].

*-убан:* кәмәнд учын тутубан Ғәли инар [111]; жүмләси қаршы келүбән күрүштиләр [251].

*-гүнчә:* һәр бириси күтәргүнчә алдылар [229].

«Мәхәббәтнамә» текстында хәл фигыльләр: *-п, -а, -у, -йу, -гач, -кинчә, -мышча:* булутлар йел тек күкрәп йүрүрләр [11]; күңил сиздин алып кимә бирәйин [284]; кўчүм йеткинчә күп қылдым вафалар [144] ~ күчүм йетмишчә көп хидмәт қылайын [39].

«Гөлестан бит-төрки» текстында *-п* кушымчасының бу чорда универсаль булуы билгеләнә, күп төрле функцияләре теркәлгән: қуры итмек ашар һирқә кийәргә чүн канәғәтмән [82v-3]; ол фәқир қорқур үчүн ала билмеди ол ташны алып сақлады [32r-10, 11], йегирми алтун бирүрләр ким дәги бир өзгә йергә барғыл дип [221] һ.б.

*-а/-ә* кушымчалы фигыльләр төп фигыль белән бер үк вакытта үтәлгән эш-хәлләрне белдерә: ол пәһләwан йигит билән ойнай күлә килүр [149r-2]; йугүрүр артымызча халқ күлә [157v] народ»; ол корқа йүрүр сендин [18r-2]; йығыла тура китәр ирди [26v-5] һ.б. *-а* формалы фигыльләр модаль конструкцияләрдә теркәлгән: тута билмәди [94v-2], қутула билмәди [95r-2], бахиллық қыла билмәди [99v-1], ола билмади [100v-6] ирдәмсизләр әрдәм ийәсин көрү билмәс [33 v].

*-убан* кушымчалы традицион фигыль формалары еш очрый: аwчы сықыбан кейикләр аwлар wақтын арслан көрубән тутуп терисин йыртар [105r-6, 7]; үңүндән үркүбән учты тизилмиш там үзә қушлар [119]; кәрәм билән ачыбан күч билән аны йарма [22r-8]; ол ир ким оқ атыбан қыл йара нишан урғай [149-v-5] күлүбән айтты [116r-12]; қәфил йүрүбән усал болма [14r-8]; йүрүбән бир киши арқун түн wә күн [167р-3] һ.б.

Юклык аспекты *-майын/-мәйин, -майынча* формалары белән белдерелә: даим кириширләр ит билән мачы тег болмайын алар бири бириндән рази [180]; ашықмайын атыңны сүргил ақрур [271]; өлүмни аңмайын алтун ғәмин йир [173 r-7]; иштихалары ғәлиб болмайынча тағәм йемәгәйләр [83 r-12] һ.б.

*-галы* кушымчалы фигыльләр сирәк теркәлгән: йолунда баш ойнар чан тәркин урурмән көргәли дилдар көркин [113r-12, 13].

«Хөсрәү вә Ширин»дә *-п/-ып/-ип, -уп/-үп* кушымчалы хәл фигыль актив кулланылышка ия: қуруп чимкән үзә шаһына хош тахт [52], кирип тәркин бақып ишикдин айтыр / килип дастур тилер ким кирсә Шавур / мәлик сәвнүп сәкирмәккә тиләди [54v]; алып сәвнү илин Ширин үбүп ғиззәт қылып китәрди мәһрин [140-1, 2] һ.б.

*-а, -у* кушымчалы хәл фигыль текстларда ялгыз да, кабатланып та кулланылган:бақа йузүңкә күңлүмни ачайын [85v]; килә айтур йимә ий шаһ қазғу [195]; ғишрат қылу отурурда бир күн [57]; йүрүрләр хош күлә ойнайу һүррәм [40]; йир үпти шаһқа сәвүнү қувану [58]; үпүшү ойнашу олтурдылар хош қылу бир бириңә таңа тәги һуш [200]. *-а, -ә* кушымчалы хәл фигыльләр аналитик фигыльләр составында да кулланыла: сача башлады [1028]; сора башлады [52]; үгә башлады [119]; айыту башлады [162]; аша бирди [9]; сүзләшү турсун [106]; бақа қалур [199]; күрә билмәз [11] һ.б..

*-убан* традицион кушымчалы фигыльләр исә санаулы мисалда теркәлгән: биргә килибән болуп йолдашым [231].

*-гач/-гәч* формалы региональ күрсәткеч 11 мәртәбә кулланылган: хараҗ алғач кәлүр ол тәгсә Румға [6v-11]; басқақ һарач улғаш қылур һәр дам илчи [44r]; кичә болғач қонаққа тарғадылар [52v]; қопуп отурғач айды [159]; сорарсыз мән ишитгәч йаззы билдим [186v] һ.б.

*-гынча:* сүз айғынча нагаһ вақты йитти [96v]; таң атқынча қылу бир бириңә һуш [18r]; һүнәр күргил ғайыб күргинчә зинһар [160] һ.б.

Хәл фигыльнең юклык аспекты сирәк очрый: қыйаситип сүз айды тапмадин йол [1337]; үзин килбәмәдин ашқара қылды [676] һ.б.

Алтын Урда чоры әдәби истәлекләр телендә теркәлгән хәл фигыльләр *-а/-ә, -ү, -ып/-еп, (-уб/-үб), -убән, -у/-ү, -йу/-йү,* сирәгрәк *-ун/-үн, -анчә/-әнчә, -галы / -гәле , -гыча, -гынча, -гач* формаларында килә. Бу чорда *-ып/-еп, -у/-ү, -йу/ йү, -а/-ә* кушымчалы хәл фигыльләр иң актив кулланылган форма булып тора, традицион әдәби телгә хас күрсәткечләр перифириядә, ягъни сирәк кулланылышка ия: *-убән, -ун/-үн, -анчә/-әнчә, -галы/-гәле.*

Яңа формалардан *-гач* вариантлы хәл фигыльнең әдәби әсәрләр теленә үтеп керүен күзәтәбез. Әлеге форма, бигрәк тә, Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә еш теркәлгән.

«Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхәббәтнамә» текстларында *-а/-ә, -у/-ү* кушымчалы хәл фигыльләр

кулланылышында кайбер үзенчәлекләрне билгели алабыз, борынгы төрки әдәби телгә хас нормалар саклану белән беррәттән, яңа – хәзерге татар әдәби теленә хас парлы кулланылышы теркәлгән: таш бирлә ура қамуғыны һәлак қылды [КР. 16]. Тойа тәғәм йемәдим [НФ.] килә айтур [ХШ. 195], ол қорқа үрүр сәндин [Гб. 18]; чагыштыр: йир үпти шаһқа сәвүнү қувану [ХШ. 58], йүрүйүрләр күлә ойнайу [ХШ. 40], күлә ойнайу ичсүнләр бу әсхаб [Мн. 125].

*Исем фигыльләр.* Алтын Урда чоры әдәби истәлекләр телендә традицион әдәби телдән килә торган *-мак/-мәк* кушымчалы исем фигыль актив кулланылышка ия:

«Кыйсасел-әнбия»: таш атмақ хаҗиләргә сүннәт қалду [311-17]; ошбу китмәкидин өлмәкимни тиләр ирсәң [510-13]; Кабил Һабилни үлтурмәкиңә мән сәбәб ирдим [9-13], сөзләри өтмәди анда кирин оғлан өлтүрмәк қалды [14-12] һ.б.

«Нәһҗел-фәрадис»тә: йалған сүзләмәк йаусыз имгә тәкүрүр [381-2]; ғилем истәмәк фарыз турур [230-12]; бураққа минмәк тиләди [52-13]; уғлан туғурмақ тиләйурсән [234-3], хатунум уғлан турур маққа салих булды [243-14]; намазны қалдурмаққа шариғат изиләри рүхсәт бирмәдин турурлар [241-1] һ.б.; *-мақ үчүн:* бизләр урушмақ үчүн килмәдүк [36-5]; дәрәҗәләри җүмләдин йүксәк болмақ үчүн қулду; туқсан тивә нишан қылды Қағбәдә қорбан қылмақ үчүн [37-5]; *-мақ кәрәк:* нәтәк бармақ кирәк Мәдинәгә [231-10]; йунуғ әхкәмини билмәк кәрәк [230-7]; нәфескә ағыр әмгәклар йүкләмәк кәрәк [270-6]; *-мақ бирлә:* йолда үкүш имгәнди ачлық бирлә йазағ йүрүмәк бирлә [113-8]; ол күнләкни күрмәк бирлә ани күрмиш тег болса [215-11]; һәмишә йығламақ бирлә [241]; *-мақ турур:* тәқый файдасы һауф турур йәғни Хақ тәғаләдин қорқмақ турур [233].

Юклыгы сирәк очрый: тибрәтмәк бир йердин бир йергә бармақ әрмәз [229-8].

«Җөмҗөмә солтан» текстында: титрәмәк тутты мәни [19с.13]; миң һүнәр угрәнмәк [20б.11]; күлдиң дүнйайа кетмәк кәрәк бар күчүң йиткүнчә хайыр итмәк кәрәк [15а.15,16].

«Кисекбаш» китабында: уйур девни үлтүрмәк ирлик дәгил [163], титрәмәк тутты мәни [А.19а.13], миң һүнәр үгрәнмәк [А.20б.11].

«Хөсрәү вә Ширин» текстында нигездә *-мақ* формасы актив, *-ыш* варианты сирәк теркәлгән.

*-мақ:* сүчүг сүз үчрә ағу кизләмәк бу [174-10]; гүрини экситүр ол қазғу йутмақ [58-3]; маңа берди йазмақ оқумақ билиг [235-3]; гүл

үзрә нүск сачмақ қылды ғәдәт [18-18]; отурмақым бу йердә онуң үчүн [116-4]; һ.б.

*-мақлық* (14 тапкыр кабатлана): аны билмәклик үмәз бизгә әрмәз душvар [5-15]; билиг берди аны билмәклик үчүн / бәшәрәт берди утанмаклық үчүн [5-17]; йәнә үзрәди килмәкликкә шақи [136-15] һ.б.

*-ғу/-гү:* қылды аның тег үлгүгә рай [101-11]; не олтурғу мун тег қазғу йейү [110-12]; нечә тотлығ тирисәң ачығ үлгү [101-3]; қачан тәбрәтсә ол чәң урғуға қол [191-6]; йузүң күргүгә ғаләм һалқы мустақ [13-12-28].

*-ыш* (5 тапкыр теркәлгән): йүрүшүң қандын үзүң қайу йердин [37-7], әгәр күк үрзә һуд болса турушум мәлик һүкминдә болғай олтурушум [166-5], турушуң һәм совуқ турма атың сүр [180-19].

*-у* (бер мәртәбә теркәлгән): нитәк ким тағқа айса бир киши тағ ол сүзин оқ қайтару бәз [200-18].

«Мәхәббәтнамә» текстында: үлүмдүр бизгә занансыз тирилмәк мухал ирүр тәнә җансыз тирилмәк [373]; түгәтмәк лиққа Хақ бирди ғинайат [441]; сүйүрмән күзни сизни күрмәк үчүн / йүрүрмән йердә изни күрмәк үчүн [260]; айағың өбмәгин қулқулды ғадәт [350].

«Гөлестан бит-төрки»дә: от сүндүрүр күз қоймақ йыланүлтүрмәк йигит иши дәгүл [25] йигиткә йемәк ичмәк кетүрдиләр [185], бутиләнмәк адамигә күп хисалат келтүрүр [170], халқның килмәги солтанат күркидир [32], қадими йаранлар хақ сүзни сүзләмәкдән сукут еттиләр, ғәҗаибләр күрмәк ишитмәк таншуқ / шәһәрләр тамаша қылмақ иски ирәнләр шөһбәтинә йетмәк / дағы йаңы достлар хасыйл итмәк [97r-4-6]; аны күрмәмәк мәңа ол қәдар күч келмәс [240] һ.б.

*-мақлық:* йаwузға ийгүликни қылмақлық әйләдир бил [15р-8]; күрүнмәклик кишигә ғайиб болмас [67r-8].

*-мақ кәрәк:* аны үлтүрмәк кирәк дағы бири айтты аның тилин кисмәк кирәк [44r-23]; ғүмр мал җәмиғ итмәк үчүн дәгүл [159v]; җан аманатдыр аны бирмәк кирәк [56v-7].

*-ыш:* хамр ичип уруш итип киши үлтүрүп турур [88v-5]; ики ақыл ара уруш болмас [108r-8]; аны урушта сақынма [149v-6]; бир үпүшкә җан алыр миннәт қылур [129r-6]. Парлы: атың ким сифатың не турур келишиң келмишиң қайдан [226].

Традицион әдәби телгә хас *-мақ* норма булып тора. Асылда кыпчак телләре өчен хас булган *-у, -ыш* формалары Алтын Урда чорында әдәби телгә керә башлаган дигән нәтиҗә ясый алабыз.

*Инфинитив.* Инфинитивның Алтын Урда чоры истәлекләрендә -*мага* һәм -*мақға* формалары актив кулланылышка ия.

«Кыйсасел-әнбия»дә: кишиләр кәлиб асрамақға қулғайлар анчада соң асрамақға алғыл [10-7]; сувумыз йоқ аш итмәккә [515-1]; асрамакға алур болдылар [10-8]; Салихны өлтүрмәккә оғрадылар [16-1], бут тутмаға таш тиләдиләр [7-21] һ.б.

«Җөмҗөмә солтан» текстында бары -*маға* формалы инфинитив 4 мәртәбә теркәлгән: мәни қучмақға зар [44-4]; сифат қылмаға болмаз сүз билә [21б-5]; қалды ол үз қуллығун тикүрмәгә / тирилик шүкрәнәсин [23б-7].

«Кисекбаш китабы»нда: -*маға:* тиләр ирди ол башны күтәрмәгә / Мустафануң қатына китәрмәгә [37].

«Хөсрәү вә Ширин» текстында: -*ырға:* тиләб табмады һич фурсат баруpға йоқ ерди чара һәм күлтүрүргә [103-20]; туруқтылар барурқа һидмәтингә [12-263]; барырға чарасын сәбдиз қылдым [28r].

«Мәхәббәтнамә» әсәрендә -*ырға* кушымчасы кулланылган: сениң ғыйшқында сайрарға Харәзми [174]; -*маға:* йырақ мин бақмаға имлан йоқ әй җан [168].

«Гөлестан бит-төрки» -*маққа/-мәккә, -маға/-мәгә, -ырға:* қылыб тәүбә қутулмаққа болур тәңри ғазабындан [62v-5]; тиләнмәккә девлетиндин мәхрүм турурлар [153-9]; кимичинин илиндән алмаға ала билмәдиләр [100v-5]; қутулмаға тиләсәң Хауф илиндин [20р-1]; қысас итмәгә илтүрләр [88v-6]; сатмаға килүр иди [88р-5] һ.б.

-*ырға:* зарурәт халәтиндә ким қачарға тапмаса бир йол [8v-13]; буйурса биш йумуртқаны алурға күч бирлә султан [31р-9]; үч алурға душманындин wақт бар [32v-11].

Инфинитивның Алтын Урда чоры истәлекләрендә -*маға* һәм -*мақға* формалары актив кулланылышка ия. «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхәббәтнамә», «Гөлестан бит-төрки» текстында -*ырға* вариантының теркәлүен сөйләш үзенчәлекләренең чагылышы дип карау дөрес булыр. Идел буенда әлеге форманың әдәби телгә нәкъ Алтын Урда чорында үтеп керүе текстлар белән дәлилләнә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Алтын Урда – Евразиядә урта гасырларның иң зур дәүләте, элеккеге күчмә һәм яңа шәһәр мәдәниятенең классик симбиоз кушылмасын тәшкил иткән цивилизация үзәге булган. Идел буе Болгар дәүләте Алтын Урда составында үзенең яшәешен дәвам итә, язма традицияләр һәм җирле сөйләм сакланып кала. Әдәби әсәрләрнең грамматик формаларының кулланылыш үзенчәлекләрен

өйрәнү XIV йөзнең урталарына Алтын Урданың мәркәзе булган Идел буенда традицион әдәби телнең көчле йогынтысында булган, шул ук вакытта кыпчак элементларын күбрәк, угызныкын азрак алган үзенә бер аерым региональ әдәби тел нормалары ятуны дәлилләргә мөмкинлек бирә. Безнең борынгы бабаларыбызның бу язма китап теле хәзерге тел тарихында *иске татар әдәби теле* термины белән аталып йөртелә.

Алтын Урда чоры әдәби әсәрләр телендәге төрле килеш формаларының кулланылыш чагыштырмасын өйрәнү шул чорда традицион әдәби телгә хас уйгыр-кыпчак төрләнеш тибыннан сөйләм теленә хас кыпчак тибына күчешне, кыпчак теленә хас нормаларның өстенлек алуын раслый. Уйгыр-кыпчак төрләнеше Насретдин Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия», Мәхмүд әл-Болгариның «Нәһҗел-фәрадис», Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрләрендә өстенлек алган. Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» һәм «Кисекбаш» әсәрләре теле кыпчак төрләнеш тибына нигезләнгән, бары чыгыш килешендә традицион *-дин* кулланылган. Иялек килешенең кулланылышында нигездә бердәм нормалар саклануын күрсәтә. «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис» текстларында иренләшү гармониясе эзлекле сакланган, «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхәббәтнамә», «Җөмҗөмә солтан» әсәрләре телендә ирен гармониясенең бозылу очраклары бар, ә «Гөлестан бит-төрки» һәм «Кисекбаш китабы»нда бары نینک – *-ның/-нинң* вариантлары теркәлгән. *-ың* угыз варианты «Җөмҗөмә солтан»да бары ике мисалда очрады. Төшем килешенең *-ны, -ни* кыпчак варианты барлык истәлекләр телендә эзлекле саклана, тартымсыз төрләнештә норма булып тора. Угыз телләре өчен хас булган *-и* сирәк теркәлгән. Чагыштыр: «Мәхәббәтнамә»дә төшем килешенең *-ны* формасы 62 мәртәбә, *-и* варианты 3 мәртәбә кабатлана, «Кисекбаш китабы»нда *-ны* 16 мәртәбә, *-и* кушымчасы исә 3 тапкыр теркәлгән. III зат тартымлы төрләнештә *-ын* һәм *-ыны* формаларының истәлекләр телендә вариатив кулланылышы теркәлгән, *-ын* формасы кыпчак тел нормаларының саклануын күрсәтә. Юнәлеш килешнең *-қа* саңгырау вариантының «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Хөсрәү вә Ширин» телендә бәхәссез күпчелекне тәшкил итүе, традицион әдәби тел нормаларының (уйгыр-кыпчак) эзлекле саклануы турында сөйли. «Гөлестан бит-төрки», «Мәхәббәтнамә», «Кисекбаш китабы» истәлекләрендә юнәлеш килеше кушымчалары, нигездә, саңгыраулыкта-яңгыраулыкта яраша, тартымсыз төрләнештә кыпчак төрләнеше норма булып тора. Угыз телләре өчен хас булган *-а/-ә* сирәк теркәлгән. Чагыштыр: «Мәхәббәтнамә»

әсәрендә юнәлеш килешнең *-а/-ә* формасы 10 мәртәбә, *-қа/-ға* варианты 6 мәртәбә кабатлана, «Кискебаш китабы»нда *-а/-ә* 15 мәртәбә, *-қа/-ға* кушымчасы исә 90 тапкыр кабатлана. III зат тартымлы төрләнештә *-н + ға, -н + а, -ы + ға* юнәлеш килеш формалары теркәлгән. «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Хөсрәү вә Ширин» текстлары *-н + ға,* ягъни уйгыр-кыпчак төрләнеш тибына нигезләнгән, «Гөлестан бит-төрки», «Мәхәббәтнамә», «Кисекбаш китабы», «Җөмҗөмә солтан» текстларында *-н + а* төрләнеш тибы эзлекле саклана, «Гөлестан бит төрки», «Мәхәббәтнамә», «Кисекбаш китабы»нда бары әлеге күрсәткечләр генә килсә, «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Җөмҗөмә солтан» текстларында *-н + ға, -ы + ға* вариантлары кулланылган. Тартымсыз төрләнештә юнәлеш килеш кушымчалары аерым, тартымлы төрләнештә исә кушылып язылган. Борынгы төрки нигез телдәге охшату-чагыштыру, корал килешләре әдәби тел традициясе буларак сакланган, чагыштырмача сирәк очрый. Язучылар тирән кичерешләрне, тормыш күренешләрен сыйфат сүз торкеме ярдәмендә тасвирлап, эмоциональ-поэтик яңгыраш тудыру, мәгънәне тулырак ачуга ирешкәннәр. Алтын Урда чорында язылган әдәби әсәрләр телендә төрки-татар, гарәби һәм фарсы чыгышлы сыйфатлар урын алган. Контекстта алынмалар борынгы төрки телдән килгән вариантларга синоним булып, сөйләмнең төгәллегенә, сәнгатьлелегенә ирешүдә әһәмиятле чара булып торалар. Әдәби истәлекләрдә әйбер һәм күренешләрнең төсен белдергән сыйфатлар, кешенең характерын билгели торган лексик берәмлекләр күпчелекне тәшкил итәләр. Саннарның кулланылышында традицион әдәби телдән килә торган борынгы төрки телгә хас формаларның, орфографиянең норма булып торуы күпсанлы мисаллар белән дәлилләнә. Истәлекләр телендә саннарның биш төркемчәсе дә урын алган, алар, үзләренең семантик табигатеннән тыш, стилистик роль уйный.

Хикәя фигыль күптөрле формалар белән белдерелгән. Үткән заман хикәя фигыльнең истәлекләр телендә *-ды, -ган (турур), -мыш* һәм *-ып (тур)* формалары теркәлгән. *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы билгеле үткән заман хикәя фигыльнең актив форма булуы күренә. Алар нигезендә төзелгән тиңдәш хәбәрләр зур урын тота, башлыча стилистик максат белән кулланылганнар, процессның динамикасын, я бер-бер артлы агышын бирү өчен файдаланылганнар. I зат берлектә һәм күплектә әсәрләр текстында иренләшкән вариант кулланыла: чықдым, битидим; күрдүм; биттим, айттым, пиширдүк, қылмадуқ, астуқ, йәттүк; *-дымыз:* бардымыз һ.б.

Нәтиҗәле үткән заманның *-мыш, -ган турур, -ып [турур]* формаларының кулланылышы чагыштырмача сирәк. *-мыш, -ган* формалары төрки телләрне классификацияләүдә төп күрсәткечләр булып тора, әмма тикшеренүләрдән күренгәнчә, ике вариант та Алтын Урда чоры истәлекләрендә сирәк, күпчелек очракта III зат берлек санда кулланылган.

*-ган* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль барлык истәлекләрдә очрамый, фәкать Болгариның «Нәһҗел-фәрадис», Котбның «Хөсрәү вә Ширин» һәм Харәзминең «Мәхәббәтнамә» әсәрләрендә теркәлгән. «Нәһҗел-фәрадис» текстында исә *-ган* формасының перфект мәгънәсе *турур* ярдәмче фигыле белән көчәйтелгән: билгән турур, офтанған турур. Халык сөйләшләренә хас кыпчак формасының әдәби телгә керә башлау моменты теркәлгән дип фаразлый алабыз.

*-ып (турур)* кушымчалы фигыль формасының берлек санда зат белән төрләнеш парадигмасы теркәлгән. *-ып (тур, турур)* кушымчалы фигыльнең төрле вариантларда саклануын сөйләм теле тәэсирендә әдәби телгә үтеп керүнең башлангыч этабы дип бәяләп була: тәрк етипмен [Гб.], сатгын алып турурмән [НФ.], йалбарыбмән [ХШ.], алыбсән [Гб.], түшүп турурсән [НФ.], айтып дурурлар [Гб], түшүптүр [Мн.] һ.б. Алтын Урда чоры язма истәлекләре телендә *-ган турур, -ып* [*турур*] формаларының кулланылышын күзәтү, әдәби телгә сөйләм теленең йогынтысын, әдәби телдә урын алган региональ үзенчәлекләрне күрергә мөмкинлек бирә.

*-а/-ә* кушымчалы хикәя фигыль Алтын Урда чоры истәлекләре телендә хәзерге заман мәгънәләрен белдерү өчен кулланылган, Болгар чоры истәлекләре текстында *-а* күрсәткечле фигыльнең киләчәк заман мәгънәсе теркәлгән. Алтын Урда чоры язма истәлекләре телендә *-р/-ар/-әр, -ур/-үр, -ыр/-ир* кушымчалы хәзерге-киләчәк заман формасы һәр ике семантик яссылыкта, хәзерге заман һәм шулай ук киләчәк заман мәгънәсендә шактый еш очрый. Киләчәк заман *-гай* формасының норма булуы билгеләнә, шул ук вакытта *-гу, -ысар, -гучы* традицион формаларның «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Гөлестан бит-төрки», «Җөмҗөмә солтан» текстларында спорадик кулланылышы күзәтелә.

Алтын Урда чоры истәлекләрендә теләк наклонениясе I зат берлектә *-айын/-әйен, -айым, -гам, -и* һәм күплектә *-алум/-әлүм, -алуң, -алым, -әлең, -алың, -галың/-гәлиң, -алық* вариантларында теркәлгән.

Әсәрләр телендә сыйфат фигыльнең төрки әдәби телдә билгеле барлык вариантлары урын алган: *-ған/-гән, -мыш/-меш, -ан/-ән, -дык/*

*-дек, -ар/-әр, -ур/-үр, -гучы, -гу, -дачы, -асы.* Өйрәнелә торган чорда норма булып *-ган/-гән, -мыш/-меш, -ар/-әр* кушымчалы фигыльләр торган, традицион формалардан *-ан/-ән, -дык/-дек, -гучы, -гу, -дачы* варианты аерым мисалларда гына кулланылган. Бу чор әдәби телендә *-асы* кушымчалы киләчәк заман формасының әдәби телгә үтеп керүе теркәлгән.

Алтын Урда чоры әдәби истәлекләр телендә теркәлгән хәл фигыльләр *-а/-ә, -ү, -ып/-еп, (-уб/-үб), -убән, -у/-ү, -йу/-йү,* сирәгрәк *-ун/-үн, -анчә/-әнчә, -галы/-гәле , -гыча, -гынча, -гач* формалары да килә. Бу чорда *-ып/-еп, -у/-ү, -йу/-йү, -а/-ә* кушымчалы хәл фигыльләр иң актив кулланылган форма булып тора, традицион әдәби телгә хас күрсәткечләр перифириядә, ягъни сирәк кулланылышка ия: *-убән, -ун/-үн, -анчә/-әнчә, -галы/-гәле.*

Яңа формалардан *-гач* вариантлы хәл фигыльнең әдәби әсәрләр теленә үтеп керүе бигрәк тә Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә еш теркәлгән. «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхәббәтнамә» текстларында *-а/-ә, -у/-ү* кушымчалы хәл фигыльләр кулланылышында кайбер үзенчәлекләрне билгели алабыз, борынгы төрки әдәби телгә хас нормалар саклану белән беррәттән, яңа – хәзерге татар әдәби теленә хас парлы кулланылышы теркәлгән.

Үзенең традицияләре белән истәлекләрдә чагылган әдәби тел борынгы төрки, карахани-уйгыр әдәби телгә барып тоташа, бу –традицион кушымчаларның саклануында чагылыш таба. Текстларның грамматик төзелешен, бигрәк тә исемдә килешләр системасын, фигыль сүз төркеменең кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү язма истәлекләр телендә кушымчаларны бирүдә вариативлык өстенлек алуны билгеләргә мөмкинлек бирә. Әдәби әсәрләр телендә традицион формалар белән янәшә шул чор гомумхалык сөйләм теле нормалары эзлекле кулланыла. Тикшеренүләр төрки тел белемендә шактый киң таралган карашлардан – XIV йөзнең урталарына Алтын Урданың мәркәзе булган Идел буенда караханидлар дәверендәге уйгыр әдәби традициясенең көчле йогынтысында булган, шул ук вакытта кыпчак элементларын күбрәк, угызныкын азрак алган үзенә бер аерым әдәби тел – Идел буе региональ әдәби тел формалаша дигән фикерне дәлилли.

## 3. КАЗАН ХАНЛЫГЫ ЧОРЫ ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ӘДӘБИ ТЕЛЕНЕҢ МОРФОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Теге яки бу халыкның тарихи үсешенең билгеле бер чорындагы тел торышы язма истәлекләрдә теркәлә. Иҗтимагый, сәяси, икътисади, мәдәни яктан дәрәҗәле булган Казан ханлыгы чорында галимнәр, шагыйрьләр, тел осталары күп булган, әмма алар тудырган ядкәрләрнең безнең көннәргә бик азы гына килеп ирешкән.

Бу чорның иң зур чыганаклары булып Мөхәммәдъяр поэмалары һәм шигыре тора. Шулай ук үзенең тел-стиль үзенчәлекләре белән башкалардан аерылып торган Өмми Камал иҗаты да галимнәрнең игътибарына лаек. Колшәриф – Казан ханлыгы тарихында күренекле роль уйнаган шәхес, рухани, җәмгыять һәм дәүләт эшлеклесе, үз халкының фидакарь заты гына түгел, билгеле шагыйре дә. Казан ханы Сәхибгәрәй тарафыннан 1523 елда язылган Сәхибгәрәй хан ярлыгы, Олуг Мөхәммәд хан оныгы Ибраһим хан ярлыгы Казан ханлыгы чоры рәсми эш кәгазьләре стилен күзалларга мөмкинлек бирәләр. Халык теленең үрнәкләрен кабер ташларындагы язуларда да күрәбез. Казан ханлыгы чоры кабер таш язмалары ышанычлы чыганакларның берсе булып торалар. Шул чорда Идел буенда кулланылышта булган гарәпчә – төрки-татарча сүзлек, мәдрәсәләрдә, уку йортларында дәреслек булып йөргән «Мәҗмәгыль-кавагыйд» хезмәте, зур күләмле Коръән тәфсире кебек истәлекләр Казан ханлыгы чоры язма әдәби телен күз алдына китерү өчен әһәмиятле роль уйный.

Хезмәттә Мөхәммәдъярның «Нуры содур» поэмасының Россия Фәннәр Академиясе Көнчыгышны өйрәнү Институтының Санкт-Петербург филиалындагы В 4417 номерлы кульязмасы [НС], «Төхфәи

мәрдан» поэмасының Россия Фәннәр Академиясе Көнчыгышны өйрәнү Институтының Санкт-Петербург филиалындагы В 50 номерлы кулъязмасы [ТМ], «Бакыргани» китабыннан Колшәриф шигырьләре [КШ], Өмми Камал шигырьләренең Казанда Чиркова тәбгыханәсендә 1897 елда басылган китабы [ӨК], М.З. Хөсәеновнең «Тәварихы Болгария» хезмәтеннән Мөхәммәд Әминнең «Гыйкаб» шигыре, Казан федераль университеты Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең сирәк китаплар бүлегендә, татар археографы С. Вахиди 1928 елда Спас кантоны Көек авылыннан алып кайткан «Гарәпчә-төрки-татарча сүзлек» кулъязмасы [Гс], Казан федераль университеты Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең сирәк китаплар бүлегендә Т 40 номеры белән саклanган «Җәмиг әт-тәварих» истәлеге кулъязмасы [«Җәмиг әт-тәварих»], 1958 елда Казанда табылган һәм хәзерге вакытта Татарстан милли музее фондында саклана торган Коръән тәфсире [Кт.] чыганаклар буларак өйрәнелде.

Шагыйрьләребез Мөхәммәдъяр һәм Колшәриф әсәрләре, «Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлеге [ЗвК], Өмми Камал әсәрләре, «Сираҗ-эл-кулуб» дигән зур күләмле проза әсәре, ярлыклар, 1581 елда язылган гарәпчә-төрки-татарча сүзлек, Коръән тәфсире, фәнни стильне чагылдырган «Мәҗмәгыль-кавагыйд» истәлекләре, Мартиньян Иванов төзегән хрестоматиядән Мөхәммәдъярның «Нәсыйхәт» шигыре XV–XVI гасыр иске татар әдәби телендә сүз төркемнәрен өйрәнү өчен төп чыганаклар булып тордылар.

### 3.1. Исем

Фәндә «Төхфәи мәрдан», «Нуры содур» поэмалары һәм «Нәсыйхәт» исемле бер шигыре белән билгеле XVI йөз шагыйре Мөхәммәдъяр әсәрләре Казан ханлыгы чоры язма әдәби телен күзаллау өчен иң әһәмиятле чыганаклардан исәпләнә.

Исемнәр ясалышында, башлыча, исем, сыйфат, алмашлык, сан катнаша.

Мөхәммәдъяр поэмаларында исемнәр ясалуда киң кулланыла торган берничә аффикс бар: *-луқ/-лүк, -лық/-лек, -чы/-че, -даш/-дәш.*

*-луқ/-лүк, -лық/-лек* кушымчалары исемнәргә, сыйфатларга, сирәк кенә алмашлыкларга, саннарга ялгана. Ул, төрки һәм алынма нигезләрдән сүзләргә ялганып, абстракт мәгънәле исемнәр ясый: зибалық (зиба + лык), наданлық (надан + лық), солтанатлық (солтанат +

лык), дустлық (дуст + лық), олуғлуқ (олуғ + луқ), ақлық (ақ + лық), қоллық (қол + лық).

*-чы/-че* кушымчасы – шулай ук продуктив кушымчаларның берсе. Бу аффикс, төрки һәм алынма нигезгә ялганып, исемнәр ясый. Бу сүзләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

– ясаучы нигез белдергән сыйфатка ия кешене: йаланчы (йалан +чы) [ТМ. 49];

– ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән шөгыльләнүчене: утачы (ут ‘үлән’+ ачы) [ТМ. 57а], доғачы (доға + чы) [НС. 40а].

*-даш/-дәш* кушымчасы:

– ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәттә катнашучы затны: йулдаш йул + даш [ТМ. 53б];

– ясаучы нигез белдергән нәселгә бәйле затны: қәрдәш (қарын + даш) [ТМ. 49б].

*-мыш/-меш:* (йимеш: йи + меш) [ТМ. 56а].

*-лаг:* утлағ (ут’ + лағ) [ТМ. 51б].

*-қ:* қарқ (қара + қ) ‘караш’ [ТМ. 52б], (қунақ (қун + ақ) [ТМ. 54а].

*-қыч/-кеч:* ачқыч (ач ‘ачу’ + қыч) [НС. 57а].

*-мур:* йағмур (йағ ‘яу’+ мур) [ТМ. 48б.].

*-аш:* уйнаш [ТМ. 46б].

Поэмаларда күп санда парлы исемнәр дә кулланылган. Аларның һәр ике компоненты да мөстәкыйль мәгънәгә ия, һәм алар синонимнар яки ниндидер билгеләре буенча бер-берсенә якын торалар: ғәм қайғудин [ТМ. 43а], wәғәз нәсыйхәт’ [ТМ. 65а].

Компонентлары антоним булган тезмә исемнәр дә еш очрый: хасс wә ғәм [ТМ. 65а], собх wә шам [НС. 63б], кәчә көндүз [ТМ. 54б] һ.б.

**Сан категориясе.** Мөхәммәдъяр поэмаларында исемнәр берлектә һәм күплектә кулланылган. Берлек санны белдерү өчен махсус чаралар, кушымчалар юк: нан [ТМ. 62б], балық [ТМ. 63а], көчүк [НС. 55а] һ.б.

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлегеннән мисаллар: جان – җан [ЗвК.61], شریفی – шәрифи [ЗвК. 62], شهری – шәһәре [ЗвК. 61].

Күплек саны *-лар/-ләр* кушымчасы ярдәмендә ясала һәм түбәндәгечә бирелә:لار – утлар [НС. 46], қуйлар [НС. 46], ханлар [ТМ. 45], йилләр [НС. 51],یولدوزلار – йолдызлар [ЗвК. 61b], اسیرلار – әсирләр [ЗвК.61а]. Бу очракта күплек сан формалары предметның билгесез күплеген белдерә. Борын авазына беткән сүзләргә дә хәзерге әдәби телдәге кебек *-нар/-нәр* кушымчасы түгел, *-лар/-ләр* варианты ялгана: Дөнйа эчрә барча хан+ларның ханы [НС. 62], Сәңа килсә иң + ләре һәм

сарғарыб [ТМ. 57а]. Сәхибгәрәй хан ярлыгында да бу күренешкә мисал бар: Мин бәғыд бу мөшарен иләйһим+ларға йулларында wә ин + ләрендә, сәфәрләрендә wә Хәзәрларында [Сәхибгәрәй хан ярлыгы].

Предметның төгәл күплеген сан белән саналмыш күрсәтә. Хәзерге татар телендә «күплек мәгънәсе исемне ачыклаган саннар белән бирелә» [Хисамова, 2006, б. 72]. Мондый очракка мисалларны XV–XVI гасыр язма истәлекләрендә шактый еш очратырга мөмкин: Иреклэндүрер өч йөз алтмыш бәла безғә [КШ. 38], Йите иқлим сезгә уш бәндә ирүр [НС. 42], اون بر اوتلوغ توب بار ایردی – унбер утлуғ туп бар ирде’ [ЗвК. 63а], اون كون انداغ اوروشلار بولدی – ун көн андағ орышлар булды [ЗвК. 64а]; һәм бере улдур кә аз сүз сөйләйә / ғәқыл илә йөз сүзне бер әйләйә [ӨК. 50].

XV–XVI гасыр истәлекләрендә күплек сан *күб, үкүш, барча, чуқ, җөмлә, көллә* һ.б. сүзләр ярдәмендә килә: Алдылар әсири күб улҗалары, Ул чәрекдин қылдылар үкүш әсири [НС. 62а]; килер ирде илулусдин күп кеше [НС. 44а]; ханға қылғай үкүш доға [НС. 41б]; ике ләшкәр күб қатығ оруштылар [НС. 62а], Хақ хәзрәтенә бардур күб хатам [ТМ. 59а]; һәм бере улдур кә истиғфар идә / даим истиғфары чук тәқрар идә [ӨК. 50]; барча эшдә сабыр қылғыл [НС. 53б]; көллә йулларында wә базарларында улалар [Кт. 31] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, кайбер очракларда күплек мәгънәсе морфологик һәм лексик-семантик ысулларның бергә кулланылуы белән билгеләнә, ягъни бу сүзләр күплек кушымчасы белән янәшә килә.

«Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмаларында гарәп алынмалары турыдан-туры күплек сан формасында (сынык күплек сан] кулланыла, һәм алар шулай ук *нәчә* кебек сүзләр белән янәшә килгән очрак та бар: Қылайын сезгә рәмзи нәчә әсрар [ТМ. 59б]; әсрар, Ходаwәнда белүрсән барчаны әсрар [НС. 39 б].

Өмми Камал иҗатында امّ – әни, ولد – бала, بيت – бәет), شعر – шигырь, معنى – мәгънә кебек кайбер гарәп сүзләренең күплек сан вариантлары чыганак телдәгечә саклана:امهات – уммәһәт (әниләр), اولاد – әүләд (балалар), ابيات – әбъят (бәетләр) [ӨК. 5], اشعار – әшгар (шигырьләр) [ӨК. 5], معان– мәгани (мәгънәләр) [ӨК. 49], مشاكل – мәшәкил (мәшәкатьләр) [ӨК. 16], اوقات – әүкат (вакытлар) [ӨК. 39] һ.б.

Истәлекләрдә гарәп алынмаларының күплек санда килгән формаларына *-лар* кушымчасының ялганган очраклары күзәтелә. Моңа мисалларны XV –XVI гасыр язма текстларында да күрергә була. Мөхәммәдъярның «Нуры содур» поэмасындагы Кем қылур хәлаиққа

анлар җәфа [НС. 50] шигъри юллары әсәрнең А, Б нөсхәләрендә әлеге формада кулланылса, В, Г нөсхәләрендә хәлаикъларға вариантында бирелгән. Мондый мисалларны Коръән тәфсирендә дә очраттык: йәғни бу шәйатинлары удилә атуб қумадуқлары [Кт. 46]; Ахирәтдә дәхи ул шәйатинлара ғазаб даим wардур [Кт. 47].

Мөхәммәдъяр поэмаларында җыймалык һәм күплек мәгънәсен белдергән исемнәрнең янәшә килүенә дә мисаллар да бар: Ғәдел берлә тотды дөньяны қамуғ, Тынды ғадле берлә барча кечек һәм олуғ [НС. 44а]; Тәңре фазлы берлә җәмиғ итдем китаб, Хан Сафаның wақтында, и шәйх-wә-шәбаб [НС. 43б]. Соңгы мисалда авторга гарәп алынмалары ярдәмгә килә. Димәк, күплек сан мәгънәсе, нигездә, татар теленә хас булган грамматик чаралар һәм ысуллар (морфологик – сүзнең нигезенә аффикслар ялгану һәм лексик-синтаксик – исемнәрнең аергычлары функциясендә микъдар саннары кулланылу) ярдәмендә белдерелә.

**Тартым категориясе.** «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмаларындагы тартым категориясе, хәзерге татар әдәби телендәге кебек, предметның, затның яки күренешнең икенче предметка, затка яки күренешкә мәнәсәбәтен белдерә. Мөхәммәдъяр поэмаларында бер затның яки предметның икенче затка яки предметка каравы синтетик, аналитик-синтетик һәм аналитик ысуллар белән белдерелеп килә. Мисаллар: доғасын [ТМ. 62а], атасы [ТМ. 60б], қуйныңа [ТМ. 62а], атам [ТМ. 62а], өстүмездә [ТМ. 51б], дидарымны [ТМ. 51а], атыңыз [НС. 41а], атамыз [НС. 41а].

Поэмаларда тартым кушымчалары зат һәм санның түбәндәге формаларын алалар:

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | -ум/-үм, -ым/-ем, -м | -умуз/-үмүз, -ымыз/-емез |
| II зат | -уң /-үң, -ың /-ең,-ң | -уңуз/-үңүз, -ыңыз/-еңез |
| III зат | -ы/-е, -сы/-се | -лары/-ләре |

Мисаллар:

I зат берлек сан. Имди әйтәйем китабым атыны [НС. 41а]; Дидем: и күңлүм, иҗәзәт бир мәңа [ТМ. 44б];

II зат берлек сан. Кем қулуңдин килгәнчә қыл йахшылық [ТМ. 55а]; Йите әғзәм төз йараттым мән қамуғ [НС. 64а];

III зат берлек сан. Атасы йуқунда саил килде қулғале [ТМ. 60б]; Хатыны йахшы қылдуң тиде [ТМ. 62б];

I зат күплек сан. Шөкер бары кем аның өммәтемез Йәнә кем əһле бәйтенең этемез [ТМ. 64б]; Хәйлә белә өчүмүзне алмак кәрәк [ТМ. 65а];

II зат күплек сан. Әйтә торған сүзеңез тыңламайын, Ул бой-урған эшеңез аңламайын [НС. 54б]; Серреңез сүзен мәңа белдүрдүңүз [НС. 54б];

III зат күплек сан. Телгә әйтүр бу қамуғ әндәмләре [НС. 57а]; Wатанлары ирде шәһре Фәрхәрдә [ТМ. 62б].

Татар телендә күбрәк гарәп яки фарсы сүзләреннән төзелгән фарсы изафәләре кулланыла. Алар ике сүз арасында кулланылган и хәрефе ярдәмендә бәйләнәләр [Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге (ГТРАС), б. 847–848]. Әлеге закончалык Мөхәммәдъяр әсәрләрендә дә күзәтелә. Поэмаларда гарәп изафәләренең язылышы сирәк саклана (نيت الحرام – изге йорт, سيد الكونين – ике дөнья (матди һәм рухани) патшасы, رسول العالمين – галәм пәйгамбәре, امير المؤمنين – мөселманнар хөкемдары), фарсы изафәләренең язылышы беренче сүз ахырында һәмзә билгесе (خوجء كائنات – бөтен дөнья хуҗасы, فتنء عشاق – гашыйкларны котыртучы, خدائ كريم – рәхимле Алла, جزوئ رحيم – рәхимленең өлеше, چارهء تدپر – эшне уйлап эш итү, دنائ فضل – иң күп белгән галим), яки йай (ى) хәрефе белән (امرى خدا – Аллаһ боерыгы, رضاى حق – Аллаһ ризалыгы, اهلى بيت – йорт хуҗасы, خداى كردكار – бар итүче Алла) бирелә.

Гарәп телендә изафә компонентларының саны икедән күбрәк булса, әлеге конструкция изафә тезмәсе дип атала [Аль-Аммари, 2009, б. 60]. Мондый тезмәләр Мөхәммәдъяр поэмасында да очрый: اب الفضل عثمان – «әбү-л фазыл Госман» – ‘камиллек, кешелеклелек әтисе Госман’ (Госман – Мөхәммәд сәхабәләреннән берсе һәм өченче турылыклы хәлифә), ابروى اولاد ادم – абруйи әүләде адәм – Адәм балаларының йөз аклыгы, نبي الله يعقوب – нәби Аллаһы Яғкуб – Аллаһ пәйгамбәре Ягъкуб, نبي الله سليمان – нәби Аллаһ Сөләйман – Аллаһ пәйгамбәре Сөләйман .

Поэмалардагы гыйбарәләр арасында телебездә ике гарәп-фарсы алынмасы янәшә еш кулланылып, үз вакытында татар телендә бер сүз яки тотрыклы сүзтезмә буларак актив кулланылганнары бар. Мәсәлән:

نغمةء ساز – нәгмә-и саз ‘көйләүче, җырлаучы’ (نغمة гар. – җыр, көй, ساز фар. – оста, ясаучы; төзәтүче) [ГТРАС, б. 453]; Зөлҗәлал ذو الجلال – 1. Олылык иясе, бөек. 2. *дини* Алланың исеме (ذو – ذا гар. – ия, хуҗа, биләүче, جلال гар. – бөеклек, олылык) [ГТРАС, б. 142];

فتنء عشاق – фитнә-и гошшак – гашыйкларны котыртучы (فتن гар. – бозыклык китерүче, ара бозучы, عشاق гар. – гашыйклар) [ГТРАС, б. 630].

Әсәрләрдә ялгызлык исемнәрен үз эченә алган гарәп-фарсы гыйбарәләре очрый. Алар шулай ук дини тематикалы, пәйгамбәрләр яки хәлифәләр исемнәре белән төзелгәннәр. Мәсәлән: بيت الحرام – бәйтү-л хәрам («изге йорт», ягъни Кәгъбәнең бер атамасы), عيسى نفس – Гайсә-и нәфәс («Гайсә пәйгамбәрнең тыны»), اب الفضل عثمان – әбү-л фазыл Госман («камиллек, кешелеклелек әтисе Госман», Госман – Мөхәммәд сәхабәләреннән берсе һәм өченче турылыклы хәлифә), باغ ارام – баг Ирам («Ирам бакчасы», гарәп мифологиясендә: борынгы бер патшаның җәннәт кебек эшләнгән бакчасының атамасы), نبي الله يعقوب – нәби Аллаһы Яғкуб («Аллаһ пәйгамбәре Ягъкуб»), نبي الله سليمان – нәби Аллаһ Сөләйман («Аллаһ пәйгамбәре Сөләйман»). Ике поэмада да мисалларның күплеге аларның тәрҗемә әсәрләр булуы белән аңлатыладыр: غار (йари ғәр) – Йариғәр – Мәгарә дусты: Мөхәммәднең мәҗүси гарәпләр эзәрлекләвеннән Мәккәдән китеп, тау тишегендә бергә яшәгән якын, турылыклы – сыйддикъ – дусты Әбүбәкер [ТМ, 43б.]; شير خدا («шир хода») – Шире Хода – Алланың арысланы – дүртенче хәлифә Гали ибне Әбү Талиб хакында сүз бара [ТМ. 43б]; اصحاب كهف («әсһәбе кәһф») – әсхабе кәһф – тау тишегендә яшәүчеләр. Кәһф – тау тишеге, чокыр, сыена торган урын. Биредә Коръәндә сөйләнгән җиде үсмернең тау тишегендә озак еллар гомер кичерүләре, соңыннан да дус, бер-беренә тугрылыклы булулары хакында сүз бара [ТМ, 48б]; باغ ارام («баг ирам») – Багы Ирәм – Ирәм бакчасы. Ирәм – оҗмах яисә гомумән матур бакча атамасы. Ирәм бакчасы – кешеләр һәм җеннәр өстеннән хакимлек итүче мифик тиран Шәддад тарафыннан җирдә оҗмахка һәм тәмугка охшатып төзелгән бакча [НС. 63б].

**Килеш категориясе.** Мөхәммәдъяр поэмаларында хәзерге татар әдәби телендәге кебек алты килеш: баш, иялек, юнәлеш, төшем, чыгыш, урын-вакыт килешләре күрсәтелгән.

*Баш килеш.* Хәзерге татар әдәби телендәге кебек Мөхәммәдъяр поэмалары телендә бу килеш түбәндәге функцияләрдә килә: ия: Аның сүзүнгә алданды шаһ җәһан Аны хуш сәүде, безгә булмады сан [ТМ. 45б]; хәбәр (яки хәбәрнең исем өлеше): Инғам wә ихсан йиредүр бу җиһан [ТМ. 64а]; аергыч: Әйде җәннәт суы ирмеш, аңладым Бу айған сүзене тыңладым [НС. 49б]; туры объект: Буғдайдур тиб илгә сатмағыл салам [ТМ. 55а]; Қойуғға салды йеб заһид ул заман [ТМ. 55б]; хәл: Килүр ирде ул улусдин күб тегеш, / Мал туар алтун көмүш йаз wә кыш [ТМ. 44а].

Поэмалардагы баш килештәге исем еш кына мөрәҗәгать итү өчен кулланыла: Нәчә үртәрсән дидем сән, әй күңүл, Қуй мәне үз хәлемә,

мәндин түнгел [ТМ. 42а]; Йә рәсулалах, бойур, ишедәлүм / дөнйада аңа күрә эш идәлүм [ӨК. 47]; И күңел, бил бағлама [КШ. 32].

Шулай итеп, Мөхәммәдъяр поэмаларындагы баш килештәге исемнәрнең бөтен функцияләре хәзерге татар әдәби телендәгеләре белән туры килә.

*Иялек килеше.* Мөхәммәдъяр поэмаларында иялек килеше *-ның/-нең* кушымчалары ярдәмендә ясала: Бер кешенең ике булса дошманы [ТМ. 54а]; Рәwан килтерделәр бикнең қатына [ТМ. 57а]. Әлеге форма белән беррәттән, поэмаларда, сүзнең тамыры яки нигезендә иренләшкән сузыклар булган очракта, иялек килеше *-нуң/-нүң* вариантында да бирелгән: күңүл + нүң [ТМ. 54а], қол + нуң [ТМ. 55б], әмма үксүз + нең [ТМ. 50а], Хушхун + ның [ТМ. 45б].

Поэма кулъязмаларында, *-ның/-нең* кушымчасын язганда, төрлелек күзәтелә. Бу хәл ى сузыгының язуда чагылышы яки язылмавы белән, шулай ук *-ң* графемасының язылыш вариантлылыгы белән дә аңлатыла: 1) نینک һәм 2) نیک һәм ننک. Хәтта бер биттә бер үк төрле лексемаларда кушымча төрлечә язылырга мөмкин: кешенең کشىننک [ТМ. 48б], کشىنینک [ТМ. 48б].

Ул күп очракта иялек мөнәсәбәтен билгелелек төсмере белән белдереп килә.

Өмми Камал иҗатында иялек килеше кыпчак формасы *-ның* кушымчасы ярдәмендә ясалган:

Һәм бере қылмақ дорур шөкер wә сипас / тәңренең ниғмәтләренә биқийас [ӨК. 50]

Икенчесе *-ең* кушымчалы борынгы угыз формасы:

Чөнкә белдүң wасыф хәлен мәликең / шулар йулындадүр һәм силкең [ӨК. 50].

Бер урында иялек килешенең кушымчасыз формасы (иялек мөнәсәбәтен билгесезлек төсмере белән белдерү) күзәтелде: Кәлдүк имди кирү ғазраил сүзен / сөйлийәлүм дыңла бер-бер шәксезен [ӨК. 50]. Әлеге үзенчәлек төрки телләр үсешенең борынгы этапларында да чагылыш тапкан [Щербак, 1977, с. 87].

Коръән тәфсирендә иялек килеше шулай ук угыз һәм кыпчак формалары аша кулланыла. Бер бит эчендә генә дә бу ике вариант берничә тапкыр аралашып килә: Айуң ине сәксән фарсахдур, әмма икесенең рушанлығы йарадылдығы вакты бер ди [Кт. 21]; Айуң нурынуң туқсан туқуз бәхшен алыб көнә wирделәр [Кт. 72]; Шул хөрмәнүң қорымыш инҗә бодағына тәшбийә қылды [Кт. 81]. Һәр нәснәнүң күңле wар,

Қоръәнүң күңле Йасин сурәседәр [Кт. 44]; Ул җарийәдән Ибраһимуң уғлы Исмәғил туғды [Кт. 65]. Мисаллардан күренгәнчә, бу истәлектә кушымчаның иренләшкән варианты өстенлек итә.

*Юнәлеш килеше.* Юнәлеш килешендәге исем Мөхәммәдъяр поэмаларында, Колшәриф иҗатында, ярлыкларда, нигездә, *-ға/-гә, -қа/-кә* кушымчалары белән теркәлә һәм җөмләдә кыек тәмамлык, урын хәле, вакыт, сәбәп, максат хәлләре булып килә: Бер кийезгә аны ул хуш чолғады, йибләр ишеб мәхкәм аны бағлады [НС. 49а]; Тотуб бағлады тәрәккә бәк аны сәғәт эчрә бер элкене кисте аны [ТМ. 61а]. Сабыр қылмақ иргә ирүр хуш һөнәр [НС. 52]; Эwгә барды барчаси кечек, олуғ [НС. 53]; Падишаһға тигди ул дәм бу хәбәр [НС. 53]; Мәшwәрәткә мәне лайық күрдүңез [НС. 53]; Әйделәр кем таңда ауға чықалым [НС. 57]; Андин күккә ағарлар [КШ. 29].

Мөхәммәдъяр поэмаларында бу кушымчаларны да төрлечә язу күзәтелә. Кайбер очракларда саңгырау тартыктан соң *-ға* кушымчасы кулланыла: Мән тиггән утға кеше бешмәгәй [ТМ. 55а]; Йахшылықға йахшылық килмәс димә [ТМ. 55б].

Сонор тартыкларга тәмамланган нигезләргә *-ға* суффиксы кушыла: йулға [ТМ. 56], тағға [НС. 47], ғәлимғә [ТМ. 44], Харунға [ТМ. 45].

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлегендә юнәлеш килешенә кыпчак вариантлы кушымчаның *-ға/-гә* төре генә ялгануы күзәтелә: Мисаллар: دشمن غه – дошманга’ [ЗвК. 62а], قمرغه – қәмәргә [ЗвК. 60а], قومغه – қәwемгә [ЗвК. 60а], يركا – җиргә [ЗвК. 62b, 63а], كيشى غه – кешегә [ЗвК. 63b], هواغه – һавага [ЗвК. 63b], اعتبارغه – иғтибарға [ЗвК. 60а], اوتغه – утға [ЗвК. 63b].

Өмми Камал әсәрләрендә юнәлеш килешендәге исем күп очракта угыз формасы (*-а/-ә* кушымчасы) ярдәмендә ясалган. Юнәлеш килешендәге исем җөмләдә кыек тәмамлык, урын хәле, вакыт хәле, максат хәле һәм сәбәп хәле булып килә: Гәр әмәк йирсән йула әйлә йарағ / та кем ула хақ қатында йөзең ағ [ӨК. 47]; Һәм кәрәкдүр җабраилә әй кеше / әрмәғәнләр белә һәм қыл бу эше [ӨК. 47]; Төхфәләрең чөнкә шаһә ғарз ула / сүчләреңне ғафу идүб рәхмәт қыла [ӨК. 47]; Бәс үлүмен деләйән шәхсыйа ғайан / кәрәк ун мәнзилдә дүрт дүрт әрмәғән [ӨК. 47]; Һәм кәрәдүр хақ тәғәләйә ғәзим / әрмәғәнләр кем, ул кәрим [ӨК. 47].

Мисаллардан күренгәнчә, сузык авазларга беткән исемнәргә борынгы угыз формасындагы юнәлеш килеше *-а/-ә* кушымчалары ялганганда, ике сузык аваз арасында [й] тартыгы өстәлә.

*Төшем килеше.* Төшем килешендәге исем *-ны/-не* аффикслары ярдәмендә ясала: Алдым элкемә қәләмне ул заман [НС. 66б]; Килтүрүб балықны ариғ йиргә салыб [ТМ. 63а]; Күчә эчендә йөрүр ирде йақтылықны күрүб [ТМ. 52а]. *-ны/-не* аффикслары күпчелекне тәшкил итсә дә, поэмаларның телендә угыз формасы да кулланыла: Ундүрт йәшенә йитсә үзе, бүре йиғай ғәқибәт ошбу қызы [ТМ. 52б].

Өмми Камал иҗатында төшем килешенең исемнәргә *-ны/-не* аффикслары ялганган очраклары өстенлек итә: wалыдны хуш дотуб хөрмәт қыла / кафер улурсә дәхи ғиззәт қыла [ӨК. 50]; алны атбағны дүрт йарыны / һәм қаму соңлу йаранларны [ӨК. 51].

Угыз формасы сузыкка беткән исемгә ялганган очракта, ике сузык арасына [й] авазы өстәлеп килә: йәғни кем йағландыра һәр кешейе / йаwыз эшдән иркәке wә деше [ӨК. 51].

Төшем килешендәге исемнәр туры объектны белдерәләр.

*Чыгыш килеше.* Мөхәммәдъяр поэмалары телендә чыгыш килеше *-дин* вариантлы уйгур тибында бирелә: йөзүңдин [ТМ. 47а], сүзендин [ТМ. 47б], намусындин [ТМ. 47б], ишекдин [ТМ. 47б] һ.б.

Ике төрдәге аффиксларның кулланылышы чыгыш килешендә дә күзәтелә. Сирәк кенә график яктан دان формасында бирелә торган *-дан* варианты кулланыла: тағ + дан [НС. 63б], бер-берен + дән [ТМ. 56а], [ТМ. 48б] һ.б.

Бу килеш хәрәкәтнең башлануын күрсәтергә мөмкин: Ул шәһәрдән кәчәрендә кем һаман йадына килде зәргәр ул заман [ТМ. 56б]; хәрәкәтнең сәбәбе һәм торышын: рәwан килтүрделәр бикнең катына ачыгундин сусамыш ирде қанына [ТМ. 57а]; хәрәкәтнең башлану вакыты: Wәғдәсе бер йылдин уздисә тәмам, килде шаһға барча рәғийәт хасс wә ғәм [ТМ. 53б].

Өмми Камал әсәрләренең телендә чыгыш килеше *-дан/-дән* һәм *-дин* аффикслары белән белдерелеп килә: хақдан артук нәснәләр көллә һәлак / улысадур қылсар ул хәййү пак [ӨК. 47]; әл айақ күз фәртү қолақ һәм қарын / һәм сәңа хақдан әмәнәтдүр сақын [ӨК. 50]; тәңре әмрендән нәкем фәwат улдисә / фарз wәҗиб һәм қазайа қалдисә [ӨК. 47]; wир хәбәр ул әрмәнғанлардин безә / кем бу йула ғәзим идән аны дүзә [ӨК. 47]

Өмми Камал әсәрләрендә чыгыш килешенең *-дан/-дән* вариантлы кушымчалары өстенлек итә. Кушымчаның саңгырау варианты урынына да яңгырау вариантларын куллану күзәтелә: сәңа мәнһидүр үлүмең деләмәк / кәч бу эшдән фариғ ул чәкмә әмәк [ӨК. 47].

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлегендә чыгыш килешенең борынгы уйгыр формасы *-дин* кулланыла: كوندين – көндин [ЗвК. 62a], جاندين – җандин [ЗвК. 61b], ضربتيدين – зарбтидин [ЗвК. 61b], دجال دين – дәҗҗалдин [ЗвК. 60b], درجه سيدين – дәрәҗәседин [ЗвК. 61a], ارواح لا ريدين – әрwахларыдин [ЗвК. 62b], خوفيدين – хәwефедин [ЗвК. 61b], حمرةدين – химрәтдин [ЗвК. 60a], اعمال دين – иғмәлдин' [ЗвК. 60b], قزان دين – Казандин' [ЗвК. 61b], قولوندين – кулундин [ЗвК. 61a], قورغاشيندين – кургашындин [ЗвК. 63a], اوقيدين – укыдин [ЗвК. 63b], اولومدين – үлемдин [ЗвК. 61a], روحى دين – рухыдин [ЗвК. 62b], سبعه دين – сәбғәдин' [ЗвК. 60a], سبب دين – сәбәбдин [ЗвК. 60a, 61b], طرفدين – тарафдин [ЗвК. 60a], ولايت لارندين – wиләйәтләрендин [ЗвК. 60a], ييردين – йирдин [ЗвК. 62a], يادره لاردين – йәдрәләрдин' [ЗвК. 63a].

Чыгыш килеше – төрки телләр тарихында иң соң формалашкан килеш. Ул әле V–VII гасыр язма истәлекләрендә, мәсәлән, Орхон-Енисей язмаларында очрамый, дип яза Л. Җәләй [Җәләй, 1954, б. 80]. Соңрак, бары X–XI йөзләрдә генә чыгыш килешендә *-дыйн/-дин* (язылышта), *-тыйн/-тин* (әйтелештә) кушымчасы күренә башлый. XI–XIII гасыр язма истәлекләрендә үк инде, *-дыйн/-дин* белән бергә, *-дан/-дән* формасы да очрый башлый һәм XI–XX йөз милли татар теле сөйләү теленә нигезләү процессында *-дыйн/-дин* формасы татар теленнән бөтенләй төшеп кала [Җәләй 1954, б. 80], *-дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән* вариантлары әйтелештә генә түгел, язылышта да норма булып урнашалар. Ләкин борынгы җырларда, фольклор материалларында һәм кайбер диалектларда чыгыш килешенең борынгы формасын – *-дыйн/-дин* аффиксларын әле дә очратырга мөмкин [Җәләй, 1954, б. 81]. *-дин* кушымчалы чыгыш килешен куллану татар теле диалектларында да күзәтелә. Бу форма мишәр диалектында [Мәхмүтова, 1979, б. 71] һәм керәшен татарлары сөйләшләрендә теркәлгән: Нечкәкәй, нечкә, ай иләктин, оннар иләп керттем, келәттин [Баязитова, 1986, б. 78].

*Урын-вакыт килеше.* Урын-вакыт килеше *-да/-дә* кушымчалары ярдәмендә ясалган һәм хәрәкәтнең вакытына, предметның торган урынына күрсәтә: Бүре утлағында хәрғуш йайламас, бүре ағыны таwышқан ауламас [ТМ. 15б]. «Нуры содур» поэмасы телендә күренгән *-да* кушымчалы урын-вакыт килешен чыгыш килеше урынына кулланылган очрак кызыксыну уята: эw мүңүшүндә иске мамықны алуб, ул кәчә игәрүб, киләбкә саруб [ТМ. 63а]. Ул Өмми Камал иҗатында да күзәтелә: Сүз әһле йөз бең кешедә бер кешедүр [ӨК. 69]. Мондый күренеш электән борынгы төрки текстларда билгеләнә. А.Н. Кононов

мәгълүматлары буенча, *-да/-дә* чыгыш килеш формасы борынгы уйгур телендә теркәлгән [Кононов, 1980, с. 157]. Урын-вакыт килеше чыгыш килеш функциясендә «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә дә кулланыла [Нуриева, 1999, б. 66].

Өмми Камал иҗатында күп кулланылган килеш формасы. Алдагы истәлекләр белән чагыштырганда, аффикслар язылышында аерымлыклар күзәтелми. Мәгънәсе буенча ул эшнең үтәлү вакытын һәм предметның урнашу урынын күрсәтә.

әйдүк әүүәл әрмәғән ғазраилә
нәзғ wақытында кәрәкдүр раилә [ӨК. 47].
хақ йулында барыны қылсун сәбил
кем ула җәннәт ризwан сәлсәбил [ӨК. 50].

Казан ханлыгы чоры язма истәлекләреннән Мөхәммәдъяр, Колшәриф әсәрләре телендә килеш кушымчаларының кыпчак вариантлары төп формалар булып тора, сирәк кенә юнәлеш һәм төшем килешләрендә угыз варианты да күзәтелә. Өмми Камал, 1581 елда язылган гарәпчә-төрки-татарча сүзлек, Коръән тәфсире, «Мәҗмәгыль-кавагыйд» истәлекләрендә юнәлеш һәм төшем килеш кушымчаларының угыз төре урын ала, чыгыш килешенең *-дан/-дән* варианты өстенлек итә.

*Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше.* Тартым белән төрләнгән исемнәрнең юнәлеш килеше төрле формаларда теркәлгән:

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | -ыма/-емә (17);<br>-ымға/-емгә (1) | -ымызға/-емезгә (2) |
| II зат | -ыңа/-еңә (19);<br>-ыңға (1) | -ыңызға/-еңезгә (3),<br>уңузға (1) |
| III зат | -ынға/-енгә (51)<br>-ына/-енә (58)<br>-ыға/-егә (25) | |

Күргәнебезчә, килешнең кыпчак төре өстенлек итә, карлук формасы да теркәлгән *(-ыға/-егә)* һәм уйгур варианты *(-ынға/-енгә):* Килдүң ул дәм қуйларыңа тигүрүб [НС. 45], Хәлғәт сәрwәри башыңа орғай [ТМ. 59б]; Атасы йиренә қачыб китделәр [ТМ. 66б]; Шаһ атыга бетедем ошбу китаб [НС. 41а].

«Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмаларында III зат берлектәге тартымлы исемнең юнәлеш килеше шулай ук төрле вариантларда килә. Статистик яктан караганда, сан ягыннан *-ына/-енә* фор-

масы өстенлек итә: Килде қойуғ башына су барму тиб, йөрүр ирде үзен ғәйәт сусатыб [ТМ. 55б]; Заһид йитде бағына тәмам Бичин ғиззәт илә қылды сәләм [ТМ. 56а]. Шулай ук *-ынға/-енгә* формасы да очрый: Алыб аны үзе эwенгә қыз итеб [ТМ. 52б]. Әлеге вариантлар белән беррәттән, *-ыға/-егә* төре дә теркәлгән: Эwегә килде, әйде әй хәбибә, үтүнүем бар сүкмә мәне әй зәғифә [ТМ. 62б].

Югарыда күрсәтелгән мисаллардан күренгәнчә, *-ынға/-енгә* һәм *-ыға/-егә* вариантлары бер үк сүзләргә ялгана алалар. Мәсәлән, *еw* сүзендә: *еw – енгә, еw – егә.*

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» тарихи әсәрендә угыз тибына хас *-ыға/-игә* кушымчалары кулланыла: اهليغه – әһлигә [ЗвК. 60b], آطيغه – атыға [ЗвК. 62b], آطلاريغه – атлариға [ЗвК. 60b], شريف لا ريغه – шәрифләригә [ЗвК. 61a], شماليغه – шималигә [ЗвК. 60a], ولايتيغه – wиләйәтигә [ЗвК. 60a], دركاهيغه – дәргяһигә [ЗвК. 62b], مراديغه – морадиға [ЗвК. 64b], تاشيغه – ташыға [ЗвК. 63b].

Колшәриф иҗатында ике очракка мисаллар теркәлгән: Һу бәхригә чумарлар, ғауwа булыб батарлар [КШ. 28]; Барчаны қуйныға алыб, ашна қылған дөнйадыр [КШ. 32].

III заттагы *-н* һәм *-ны* кушымчалы төшем килеше киң кулланыла. III заттагы *-ын/-ен һ*әм *-ыны/-ене* төшем килеше кушымчалары якынча бер үк күләмдә кулланылалар. Поэмалардагы *-н* һәм *-ны* кушымчалы төшем килеше сүз формалары (сүзтезмәләре) параллель рәвештә бер бәет кысаларында кулланыла алалар: Чөн китабым атыны аңладыңыз, шаһ доғасы сүзләрен тыңладығыз [НС. 42а]. Шулай ук *-ны* һәм *-н* вариантлары бер үк лексемаларга ялгану очраклары теркәлгән: Тотуб анығ сүзене шаһ җиһан ғәқл қылу башлады Нәwуширwан [НС. 44б].

*-не* аффикслары янында, поэма телендә *-ы/-е* төре дә (5 очракта) очрый: Анда әйдимсә сүзүми алмадың ич фикр итеб қолағыңа салмадың [ТМ. 57а]. Бу очракта төшем килеше кушымчаларының вариантлылыгы ачык һәм ябык иҗекләрне формалаштыру өчен кулланылуын күрергә мөмкин: сү-зү-ме, әмма: сү-зүм-не.

Өмми Камал әсәрләрендә угыз формасы актив кулланыла: ғәфил улма ғәқлыңы башыңа дир wир салатилә сәләм ишед дир [ӨК. 47].

Колшәриф иҗатында ике очракка да мисаллар теркәлгән: Һу дөррләрин тирәрләр, ғәфил йөрмә, һу тигел [КШ. 29]; Хақ зекрене қуймағыл, ғәфил йөрмә, һу тигел [КШ. 29]; Бу үлүм ширбәтин халықға эчүргән дөнйадыр [КШ. 32].

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» әсәрендә III зат берлек сан тартымлы исемнәр төшем килешендә *-ын/-ен* аффиксларын һәм *-ыны/-ене* аффиксларын алалар: معنى سن – мәгънәсен [ЗвК. 60b), مرادين – морадын [ЗвК. 63b], يورتين – йортын [ЗвК. 61b), يوزين – йөзен [ЗвК. 61b); بارچاسينى – барчасыны [ЗвК. 63a], ايشكينى – ишекене [ЗвК. 60b].

## 3.2. Сыйфат

XV–XVI гасыр язма истәлекләрендә *-лы/-ле* кушымчасы ярдәмендә ясалган сыйфатлар күпчелекне тәшкил итә. Бу төр кушымчаның язма текстларда *-лы/-ле, -лу/-лү, -лыг/-лег* формалары урын ала: Күрклүк йазы ирди, таза утлары [ТМ. 48]; Төрлүк сәчәк берлә имди бизәнүб [ТМ. 48]; Эчте ул балчыклы судин нагәһан [ТМ. 48]; Татлы су эчкәне йуғ ирди ғәрәб [ТМ. 49]; Таиб ул кем тәүбәлү қолларыңа / рәхмәти Шаһның фәраwан тәүбә қыл [ӨК. 78].

Юклык аффиксы *-сыз/-сез* төрки-татар, гарәп һәм фарсы чыгышлы сүзләргә ялгана һәм теге яки бу билгенең юклыгын ачыклый: Бәс хәйасыз кешенең иманы йук [ТМ. 48]; Кем ойатсыз кешедин килүр йаман [ТМ. 48]. Бу кушымчаның синонимы буларак, фарсы ясалма сыйфатларындагы би (بى] һәм на (نا] префикслары килә: Диде Һатиф: и фәқир wә бинәwа [НС. 41]; Хәқ рәсүле рухына сән бигәдәд [НС. 41]; Ул ирүр хөсн җәмалда бинәзыйр [ТМ. 51]; Бу зәғиф бичарә колына танлағай. [ТМ. 65]; Барча бидәрманлар дәрманы сән [ТМ. 51a]; Бирүрди наморадларның морадын [ТМ. 45a]; Булды Йусыф wаслы берлә шадман [ТМ. 52] һ.б.

Синтаксик яктан, сыйфат поэмаларда күбрәк аергыч функциясендә һәм хәбәр булып кулланыла. Мисаллар: 1) Бәс хәйасыз кешенең иманы йуқ [НС. 48]; Кем ойатсыз кешедин килүр йаман [НС. 48]; Белмәс ирдиләр сөчүк суны ауға [НС. 48]; Ғәрәб бер тазә йазыға кәлде мәгәр [НС. 48] һ.б. 2) Күрде бер күл: эче балчық, су тулуғ [НС. 48]; Йахшы уқуб мәғнәләрен белеңез [НС. 42]; Тәңренең лотфы берлә йомшақ булур НС.44]; Ул тәкәббер қылмақдин алчақ булур [НС. 44].

Сыйфатланмышыннан башка килеп исемләшкән очракка мисалларны күпләп китерергә була: Көчлүк көчсезгә тигүрмәз зийан [НС. 41].

Чагыштыру дәрәҗәсе *-рақ/-рәк* кушымчасы ала: Бер сәғәт ғадел қылмақ йахшырақ, Кем ғибадәт алтмыш йылдин озақрақ [НС. 43]; Чықар ирди ул тағыдан бер булақ, Ақар ирди сувы балдин татлыграқ [НС. 63]; Ул булақ өстүндә бетмеш бер тирәк, Сайәсе бағ Ирәмдин йахшырақ [НС. 63].

Мөхәммәдъяр поэмаларында урын алган сыйфатларны, предметның нинди билгесен белдерүләренә карап бүлгән очракта, кешенең акыл ягыннан сыйфатын, холык үзенчәлекләрен белдерә торган төркемчәләре күп санда урын ала: Ул борунги рузгярда, и йегет [НС. 6]; Арбасы берлә күтүрүб тигмә көн [НС. 46]; Ике данки буручлуг ирүр мән ана [ТМ. 46]; Белмәс ирдиләр сөчүк суны аугa [ТМ. 48]; Кем сафа булсун тиб арығ затына [ТМ. 62]; И караңғу төнни айдын қылғучи, И йазуқлар дәфтәрени йуйғучи [ТМ. 62] һ.б.

Поэмаларда кулланылган сыйфатлар арасында гарәп һәм фарсы телләреннән кергәннәре дә шактый: Ошбу Самит пәһлуан назир иде [ТМ. 59]; Ул йәһүдә җәтле нас қадир иде [ТМ. 45]; Ул кеше булур вафадар, и йегет [ТМ. 55]; Тазә утлар истәйү китәр идең [НС. 45] һ.б.

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлегендә сыйфатлар, башка сүз төркемнәре белән чагыштырганда, аз кулланылган. Ә кулланылу ешлыгы буенча, сыйфат ясагыч кушымчаларны түбәндәгечә күрсәтергә мөмкин:

*-сыз/-сез:* سانسیز – сансыз, ساغشسز – сағышсыз [ЗвК. 61а];

*-луг/-луг* кушымчалары: اوتلوغ ‘утлы’ [ЗвК. 63а].

Мәгънәләренә карап, сыйфатлар асыл һәм нисби сыйфатларга бүленәләр. Асыл сыйфатлар, әйбернең саф билгесен белдереп, аны төсе: آق – ак [ЗвК. 62а], ساری – сары [ЗвК. 62b]; күләме буенча: کیچکنه – кечкенә [ЗвК. 63а]; характеры буенча: کرانکغو – караңгы [ЗвК. 63а]; эчке билгесе аша: اخلاص– ихлас [ЗвК. 64b], یخشی – яхшы [ЗвК. 63а] ачыклыйлар.

Нисби сыйфатлар бер әйбернең икенче әйбергә булган мөнәсәбәтен билге итеп күрсәтәләр: روحی – рухи [ЗвК. 62b], سایه سی – сәяси [ЗвК. 62а].

Кол Шәриф әсәрләрендә сыйфатлардагы үзенчәлекләр бу чорның башка истәлекләреннән аерылмыйлар. Алардан еш очраганнары – *-лыг/-лег, -луг/-луг* кушымчалары белән ясалган сыйфатлар: күзи йашлиг, бәғри башлиғ булмағунча булур қандин [КШ. 34]; үмид тутмақ мөхәл ирер, капуғ бағлиғ камуғ йандин [КШ. 34].

Сыйфатлар *-лы/-ле* кушымчалары белән дә ясалган: ул қодрәтле хәкимгә, безләр тикән имәсбез [КШ. 47]. Аларны куллануның ныклы системасы юк.

*-сыз/-сез* кушымчасы предмет яки күренешләрнең нindидер билгесенең булмавын күрсәтә: Аның күңли арар булса шәфқәтсез [КШ. 39].

Кайбер кушымчалар сыйфат ясауда сирәк кулланылалар. *-уг/-иг* формасы белән олы һәм кече сыйфатлары килә: олуғ ғөмер дәрйасын қырық йылғача ағузур [КШ. 49]; йығлашдылар: хөбби! – диб, олуғ кечек барысы [КШ. 46].

Кол Шәриф иҗатында гарәп теленнән кергән сыйфатлар очрый: мән шикәстә ғәрибнең халин бер дәм сурмадың [КШ. 46]; Төшкән икән ғәзим халық, ғарик булубдыр кимәси [КШ. 46]; Қылды тәшриф шәриф-ләтыйф қоръән безгә [КШ. 37].

Предметның конкрет нинди билгесен белдерүләренә карап, Өмми Камал әсәрләрендәге сыйфатларны түбәндәге лексик-семантик төркемнәргә бүлергә мөмкин:

1) төс ягынннан билге белдерүчеләр:

بنكزومز صارى كوزمز ياش يرينه قان دوكار

Бәңзүмез сары күземез йәш йеринә қан дүкәр [ӨК. 68];

كم كچدى عمر دوشدى قارا ساچمه آغلر

Кем кичде ғомер дүшде қара сачемә ағлар [ӨК. 70];

آغ قارا صارو كوك مور اچنده

Ақ қара сары күк мур эчендә [ӨК75].

آغا قاره ساچنك بوياندى آغا

آغا قاره ساچنك بوياندى آغا

Аға қара сачың буйанды аға [ӨК. 69]

2) тышкы сыйфатны белдерүчеләр:

اچنك ياوز طشنك ايو

Эчең йаwыз тышың айу [ӨК. 82]

كوزسز بيكى نورين ظلماتمى صتيدى

Күзсез бике нурын золматымы сатиды [ӨК. 101]

3) пространствога бәйле билге белдерүчеләр:

ايراغ استامه آنى سنده يقين آرا كونكل

Йыраған эстәмә аны сәндә йақын ара күңел [ӨК. 98]

4) физик халәтне белдерүчеләр:

قللرى ننك قهرينه قاينار ماديلار قاشلار

қолларының қәһренә қайнар маддиләр қашлар [ӨК. 89]

سنكا اول قرانغو يرده كم زوادنكه قان ايكن

Сәңа ул қаранғу йердә кем зәwәдеңә қан икән [ӨК. 93]

5) акыл ягыннан билге белдерүчеләр:

حق سوزى قبول ايده ايدى منكر جاهل

Хақ сүзи қабул идә иде мөнкәр җаһил [ӨК. 101]

6) характерны, психик үзенчәлекне белдерүчеләр:

ايشنك ريا باشنك قيو

Ишең риа башың қыйу [ӨК. 82]

من رحمة الله اول صبور

Мән рәхмәтә-ллаһ ул сабур [ӨК. 83]

7) вакыт ягыннан билге белдерүчеләр:

باقی حیاته ایروشه سن بو مماتیله

Бакый хәйәтә ирүшәсең бу мәмматилә [ӨК. 103]

هم قاتی اوزاق سفردور او یول

Һәм қаты озақ сәфәрдүр у йул [ӨК. 47]

Синтаксик яктан караганда, сыйфатлар җөмләдә, исемне ачыклап, аергыч булалар:

باق بو عجایب ایشلره کم بی نیاز ایدار

Бақ бу ғәҗайеп ишләрә кем бинийаз идәр [ӨК. 105]

Субстантивацияләнгәндә, сыйфат исем үзенчәлекләрен ала: килеш, тартым белән төрләнә, берлектә һәм күплектә килә, исемнең синтаксик функцияләрен үти:

اول حبیبنك هصطفی و مجتبا و مقتدا

Ул хәбибең мостафа wә мүҗтәбән wә муқтадән [ӨК. 93].

Коръән тәфсирендә сыйфатлар кулланылышын күз алдына китерү өчен Кәүсәр сүрәсеннән кыска гына өзек китерү дә җитә. Кәүсәр сурәсенең беренче аятен автор түбәндәгечә аңлата: йәғни Хақ тәғалә бойурды кем йә Мөхәммәд без сәңа хәйр кәүсәр вирдүк, Коръән кеби вә ғилм кеби муқатил айырур морад бондан бер ырмақдур, җәннәт эчендә, балчығы мискдүр wә қомы қабуры инҗүдүр, ақлығы қардан ақдур, ләззәте балдан татлудур, ике кәнәре алтундандур, йумшақлығы сүд күбүгендән йумшакдур, қәдәхләре кәнәрендә көмешдән күкдәге йылдызлар сағышынча Бер эчем андан айруқ сусамаз әwwәл андан эчәнләр, мөһәҗирләрүң фәқирләре ула ки, тунлары керлү, сачлары тузғуқ. Бағлы қапулары анлара ачмазлар вә көрклү, ниғмәтлү ғәүрәтләре анларә wармаз, дөнйада бер хәҗәтләре йиренә кәлмәз [Кт. 66].

Алда каралган текстлардан аермалы буларак, *олуғ, катығ, тулуғ* кебек сыйфатлар бу истәлектә (Өмми Камалда да шулай] *олы, каты, тулы* вариантларында кулланыла: олу таш [Кт. 11]; тулу қәдәх [Кт. 55]; олу йылан [Кт. 59]; қаты қуәтилә [Кт. 66], қаты таш [Кт. 71], атлу ләшкәр [Кт. 96], туғры юл [Кт. 97], қаты газаб [Кт. 101], пак чәшмә [Кт. 55]. Алынма сыйфатлар да еш очрый: мөхлис коллар [Кт. 56]; салих коллар [Кт. 67]; мөбәрәк китаб [Кт. 102].

### 3.3. Рәвеш

Рәвеш – эш-хәл, билгеләрнең, сирәгрәк предмет һәм затларның процесска бәйле булмаган билгеләрен белдерә торган сүз төркеме [Татар грамматикасы, 2002, б. 318]. Язма истәлекләрдә рәвешләргә

мисаллар шактый тупланды: һәр морады тизрәк хасил ула һәр нәдин кем қурқар исә қортула [ӨК. 46]; бере улдур кем тәғәмен йийә аз, чуқ йимәкдән әйләйә ки ихтираз [ӨК. 50]; Кичә-көндүз даимән рушән ирүр, Йаз wә қыш ғәләм қәмуғ гөлшән ирүр [ТМ. 54]; мәғсыйәтләр мәнзилендән тиз кәчә таиб улуб тәүбә милкенә күчә [ӨК. 49]; Сән тәк этләр йырақдин күб өрерләр [ТМ. 47а].

«Гарәпчә-төрки-татарча сүзлек»тә рәвеш сүз төркеменә караган сүзләр шулай ук урын ала: йаланайақ [Гс. 7а], йаран wә таңлә [Гс. 83а], йөзә йөз [Гс. 92а], бер берин [Гс. 88а], чук [Гс. 83б], элгәрү [Гс. 2б] һ.б.

Казан ханлыгы чоры поэзиясендә рәвеш синтаксик яктан фигыльне, башка рәвешне, сыйфатны ачыклап килә: Мәгнәсен төрки теленчә, и йегет,/ Шәрех итәм, җан wә дил берлә ишет [ТМ. 48]; Аз нәмәрсә берлә қылды ул сәха, Хәқ ғиwазын бирде аңа үкүш ғәта [ТМ. 47]; Ташқару чыкдым, күрәрмән бер сәwар [ТМ. 51]; Мән тәқи үлгүнчә тапуғда торуб, Көчүм йитәрчә сезгә хезмәт қылғаймән [ТМ. 55]; Төрк телеңчә мәғнәсен аңла хуш [ТМ. 55]; Хәзрәтендин теләнү килдүк қәмуғ, Рәхмәтеңдин безни қайтарма қоруғ [ТМ. 48]; аз йимәк, аз айумақ, аз сөйләмәк қанки адәмдә кә wар улур мәләк [ӨК.50].

Мисаллардан күренгәнчә, рәвеш җөмләдә, нигездә, хәл функциясен үтәп килгән: Күб йөрүде аксаб, арыб йатмады [ТМ. 55]; Төрки теленчә мәғнәсен аңла хуш [ТМ. 5]; Таң йаруғач иргә бирде сатмаға / Көндәгечә тәғәм алыб қайтмаға [ТМ. 5]; Гөл гөлә қаршу ачылыб хуш бизәнди Гөлестан, былбыла қаршу қылырлар һәрбери ғиззе наз [ӨК. 51]; Кемиси бағда хуш авазилә уқыр тәсбих, кемиси юқары пәрваз идүбән ачты җәнах [ӨК. 51].

Бу чорның тикшерелә торган әсәрләрендә рәвешнең төрле төркемчәләре урын ала.

Билге рәвешләре эш яки хәлнең, билгенең сыйфатын, үтәлү рәвешен, микъдарын, күләм-чамасын белдерәләр: Бүре берлә қуй бергә су эчәр, Үрдәк берлә қарчыға бергә очар [ТМ. 41]; Һәм каты озак сәфәрдүр у йул кешейә азук кәрәкдүр анда бул [ӨК. 47]; Ғәфләт илә кәчде ғомрем аһ wә аһ сачем ақ йөзем қара эшем гөнаһ [ӨК. 51]; Һәзар дастан тутый, көмәри, һөдһәдтән, уқыр сабағ мазидан, wирерләр гуш [ӨК. 51]; Шу дәклү мәхех, сәналәр қылыр ки усый кидәр,/ дөшәр дүкәннәр эчинә йатыр бераз биһуш [ӨК. 51]; Һәм бере улдур кә истиғфар идә, даими истиғфары чуқ тәкрар идә [ӨК. 50].

Хәл рәвешләре эш-хәлнең үтәлү вакытын, урынын, сәбәбен, максатын белдерәләр: Бу җиһан фани дорыр кем буңа мәйл идарсә азмайа

эше уңа [ӨК. 51]; Һәм сиратә әрмәғән дүзмәк кәрәк, Кем кичә андан ки ғиран тизрәк [ӨК. 47]; Әйдүр әwwәл әрмәғән ғазраилә, Нәзғ wақытында кәрәкдүр раилә [ӨК. 47].

XV–XVI гасыр язма истәлекләрендә гарәби һәм фарсы чыгышлы рәвешләр шактый еш кулланыла. Мөхәммәдъяр поэмаларында һәм шигырендә *даим, даимән* – һәрвакыт, *мөдам* – өзлексез, *нағаһән* – кисәк, көтмәгәндә очракларына мисаллар теркәлде: Фәқир бинәwа мән (вә) дил шикәстә даим қылур әғдәләр күңлүмни хәстә [ТМ. 45б]; Сән мәңа әсрү мәламәт қылмағыл / Йирсезин даим шикайәт қылмағыл [ТМ. 54б]; Даимән бу сариға килгел тиде [ТМ. 56а]; Кем үзе даим зийарәтға килүр [НС, 52]; Күни булсун сүзләре аның мөдам [НС. 56]; Бер көн утун сатыб үзе нагәһан [НС. 46]; Дәрвишанә хезмәт итеб уш үзүм, Мөфлисанә ғәрыз итеб хуш сүзем [НС. 46].

Шул рәвешле, XV–XVI гасыр язма истәлекләрендә төрки-татар, гарәби һәм фарсы чыгышлы рәвешләр кулланыла.

### 3.4. Сан

Саннар иң күп кулланылган «Мәҗмәгыль-кавагыйд» истәлегеннән өзек: дәхи бу хисабә сәкез йөз йекерме ике акча әйләр имеш. Wә йахуз ул бең ике йөз отуз өч дирхәме шөйлә йазасың ٣٣٢١, бәгду бу агдади тәслис идәсен. Бу хасил улур ١١٤/٢٢٨» [17:171]. Шул рәвешле, бу истәлектә саннарга һәм цифрларга гаять күп мисал табып була.

Коръән тәфсирендә дә автор саннарга еш мөрәҗәгать итә: Кем ай мәнзилләрне утуз көндә ...идәр. Нәтикем көнәш бер йылда сәир идәр. Мукаил әйдүр. Айуң ине сәксән фарсахдур, дәкүрмидур, көнәш ине дәхи ... әмма икесенең рушанлығы йарадылдығы вакты бер ди. Айуң нурынуң туксан тукуз бәхшен алыб көнә вирделәр. Ануң рушанлығы зийәрә улды. Ай бер көнәш нурилә калды [Кт. 26]. Башка истәлекләрдә дә саннарны еш очратырга була. Все количественные числительные общетюркские. Бер [Кт. 84], ики [Кт. 851], өч [Кт. 19], бәш, йиде [Кт. 110], сәкез [Кт. 120], туқуз, унбер [Кт. 851], унике [Кт. 44], йекерме [Кт. 46], отуз [Кт. 26], қырық [Кт. 81], сәксән [Кт. 26], туқсан туқуз [Кт. 26], йөз [Кт. 110], бең [Кт. 80], ике бең [Кт. 8].

Истәлекләрдә кулланылган саннар, хәзерге көндәге парлары белән чагыштырганда, күп кенә графо-фонетик үзгәрешләргә ия. «Мәҗмәгыль-кавагыйд» кульязмасында саннар түбәндәгечә языла: بِر – *бер*, إكه – *ике*, اوج – *өч*, درت – *дүрт*, آلت – *алты*, يدي – *йиде*, طقوز – *туқуз*, اللى – *илле*, التمش – *алтмыш*, يوز – *йөз*, بيك – *мең* [МК. ]. Бу чор

истәлекләрендә *дүрт* санының һәм аннан ясалган башка төрләрнең кулланылышында үзенчәлекләр күзәтелә. Мөхәммәдъяр поэмаларында бу санның, бар очракта да дип әйтерлек, саңгырау варианты кулланыла: *түртәгү*, *түртүнче*, *түртүсе*. Әмма *ундүрт* саны составында килгәндә, аның яңгырау варианты кушыла. «Сираҗ әл қулуб» әсәрендә бу санның яңгырау һәм саңгырау авазларга башланган вариантлары кулланыла: *төрт* һәм *дөрд*. Без чыганак буларак кулланган сүзлекнең һәм мәкаләнең авторы Ә. Нәҗип, д/т тәңгәллегендә әсәрдә параллель мисаллар булса да, сан ягыннан яңгырау вариант күпчелекне ала дип күрсәтә [Наджип, 1989, с. 155]. Өмми Камал бу санны һәр очракта дүрт формасында яза: икедә терек итдүге, алтысы, дүрте, бишедер [ӨК. 69]. «Гарәпчә-төрки-татарча сүзлек»тә сүзнең башында һәр очракта яңгырау *д* тартыгы килә, тәртип һәм бүлем саннары ясалганда, *дүрденче*, *дүрдәр-дүрдәр*, ә төп сан булып кулланылганда, саңгырау *т* авазына беткән вариант очрый: дүрт айағы сәхил ат – дүрт айағы ақ ат [Гс.]. Күзәтүләрдән чыккан нәтиҗәләрне соңрак гомумиләштереп бирү максатыннан, мисаллар китерүне дәвам итәбез. *Җиде* санының кулланышында да төрлелек күзәтелә. Бу санның XVI гасыр язма истәлекләрендә *й* авазына башлануы абсолют, ә интервокаль позициядә поэзия телендә, ягъни Мөхәммәдъяр әсәрләрендә һәм Колшәриф иҗатында саңгырау тартык *т* кулланыла, ә «Сираҗ әл қулуб» әсәрендә бу санның да ике варианты да очрый. Өмми Камал иҗатында һәм «Гарәпчә-төрки-татарча сүзлек»тә бары тик яңгырау *д* тартыклы *йиде* формасы гына бирелә. Сәхибгәрәй хан ярлыгында да шулай ук. Эпитафик язмаларда, мәсәлән, Олы Нырсы авылында 1443 елда вафат булган кешегә куелган кабер ташында саңгырау *т* белән кулланыла: سكيز يوز قرق يتى دا – сәкиз йөз қырық йитедә [Юсупов, 1960, с. 81]. Ул башка шул чор ташларында да шулай... [Юсупов, 1960, с. 84].

Тугыз цифрын белдерүдә бу чорга караган барлык чыганакларда – Мөхәммәдъяр поэмалары, Колшәриф әсәрләре, Өмми Камал шигырьләре, «Сираҗ әл қулуб» җыентыгында, «Гарәпчә-төрки-татарча сүзлек», Сәхибгәрәй хан ярлыгында бары тик *туқыз* варианты гына кулланыла. Бу очрактан соң, сигез санынын кулланылышында да саңгырау тартык булырга тиеш дигән фикергә киленә һәм ул башка галимнәр (И. Әүхәдиев, Ә. Нәҗип, Ф. Фәсиев] тарафыннан да шулай укыла һәм траскрипцияләнә. Бу шулай ук йекерме санына да карый.

*Мең* санының кулланышында Өмми Камал әсәрләрендә һәм «Гарәпчә-төрки-татарча сүзлек»тә аермалар бар. Аларда яңгырау *бең*

варианты кулланыла: Эшләреңең бең дә бере бетмәсен; йиде йөз бең; йөз бең дөрлү дөрең.

*Илле* саны шулай ук ике вариантта очрый. Мөхәммәдъяр поэмаларында һәм «Сираҗ әл-қулуб» та *илле* формасы белән беррәттән, борынгы уйгур формасы *иллиг* кулланыла.

Санап кителгән мисаллардан күренгәнчә, бу саннарны куллануда XVI гасыр язма истәлекләрендә төрле вариантлар файдаланылган очраклар күп. XVI гасыр язма истәлекләрендә, хәзерге көн күзлегеннән чыгып карaганда, төп, тәртип, җыю һәм бүлем саннары кулланыла. Төп саннар бернинди кушымча кабул итмичә, санау функциясендә йөриләр һәм һәр очракта саналмышларының берлек санда булуын таләп итәләр: өч җанвар, дүрт айак һ.б. Төп саннардан истәлекләрдә, югарыда саналганнардан тыш, *бер*, *ике*, *өч*, *биш*, *алты*, *ун*, *утыз*, *қырық*, *алтмыш*, *йитмеш*, *туқсан*, *йөз* һәм шушы гади саннардан торган күп кенә кушма һәм тезмә саннар кулланыла: ун йети мең, өч йөз алтмыш, туқсан туқыз, ун сәкез бең дүрт йөз [ӨК. 67]; унсигез бең [ӨК. 63] һ. б.

Өмми Камал һәм Мөхәммәдъяр иҗатында фарсы саннарыннан *ду* – ике [ӨК. 27], *шәш* – алты [ӨК. 62] саннары очрый:

دو عالم دن بنکا محبوب مطلوب

Ду ғәләмдән бәңа мәхбүб матлуб [ӨК. 35]

اول کوناشدان شش جهت پر نور ایدی

Ул қунашдан шәш җәһәт пәр нур иди [ӨК. 46]

Әсәрләрдә гарәп саннары да ук актив кулланылган: *әхәд* – бер [ӨК. 62], *ғәшәрә* – ун [ӨК. 66], *әлф* – мең [ӨК. 64]:

تحت الشجرده هم عشر مبشره ده

Тәхтә әшшәҗәрә дә һәм ғәшәрә мубәшәрә дә.

Санның килеш белән төрләнүенә дә мисаллар бар:

یوز بنك کا یقین وار الی التنده خلیفه

Йөз беңғә йақын wap әле алтында хәлифә [ӨК. 99]

Нумератив сүзләрдән, метафора рәвешендә кулланылса да, күләм берәмлеген белдерә торган *уч* сүзе очрый:

ای بر اوچ بالچیغه سوزی سویلادن

И бер уч балчиғә сүзе сөйләден [ӨК. 3]

Әйберләрнең өлешен күрсәтә торган *икедән бер, өчтән ике* кебек өлеш саннары да микъдар саннарының бер төркемчәсе итеп карала. Аларга мисаллар Колшәрифнең кыйссасында һәм «Гарәпчә-төркитатарча сүзлек»тә очрады. Алар бигрәк тә Өмми Камал иҗатында күп. Өлеш саннарын сүзлек авторы аерым параграф итеп аерып чыгара,

әмма аларның ясалышы бүгенге көндәгедән аерыла. Хәзер өлеш саннары ваклаучысы беренче урында чыгыш килешендә бирелеп, санаучысы баш килештә килә. Сүзлектә һәр очракта ваклаучы урын-вакыт килешендә килә: бишдә бер, йидедә бер, унда бер, ә نصف – нисфун, ягъни икедән бер 1/2 сүзлектә *йарым* сүзе белән бирелә. Бу Өмми Камалда да шулай: Зирә кем сүз әһле йөз бең кешедә бер кешедүр [ӨК. 69.]; Эшләреңнең бең дә бере бетмәсүн [ӨК. 23]; Сүз әһле йөз бең кешедә бер кешедүр [ӨК. 68]. Без караган иртәгерәк чор язма истәлекләреннән мондый кулланылышны XII–XIII гасыр тәфсирендә очраттык: төртдә бер, өчдә бере. Ә Колшәрифнең «Хөбби Хуҗа кыйссасы»нда «Маллариның унундин берин безгә бирүрләр» дигән юллар бар [КШ.]. Мисалдан күренгәнчә, ваклаучысы чыгыш килешендә килә, ә чыгыш килешендәге кушымчасы шул чор башка истәлекләрендәгечә борынгы уйгур кушымчасы *-дин* белән бирелә.

Бу чор язма истәлекләрендә тәртип саны төп саннарга *-ынчы/-енче* кушымчасы ялганып ясала. XVI гасырга караган язма истәлекләрдә тәртип саннарын бирүдә, мәсәлән, икенче, өченче, дүрдүнче/дүртүнче һ.б., ягъни татар әдәби теле белән чагыштырганда, үзгәреш юк. Язуда үзенчәлек шунда: күп кульязмаларда *ч* авазы *җ* (җим] хәрефе белән бирелә. Казан ханлыгы чоры кабер ташларында тәртип саннары еш очрый: اون سکیز نچی – ун сәкизенче көн [Юсупов,1960, с. 82], اون بشنچی – ун бәшенче көн иде [Юсупов, 1960, с. 84]. Борынгы төрки чыганаклардан XVI гасыр язма истәлекләренә кадәр (М. Кашгари сүзлеге, тәфсир, «Нәһҗел-фәрадис», Болгар эпитафик язмалары һ.б.) тәртип санының *-ынч/-енч* кыска формасы актив кулланылып килә. «Сираҗ әл-кулуб» әсәрендә дә бу форма еш очрый: икинҗ, бәшинҗ, әмма сирәк кенә булса да тулы форма да кулланыла: бәшинҗи [Наджип, 1989, с. 160].

Истәлекләрдә беренче (первый) мәгънәсен бирүдә төрлелек күзәтелә. Иң актив кулланылган сүз – *әwwәл:* Қойуғға салды йиб Заһид ул заман Бичин әwwәл йабышыб чықты рәван [ТМ. 14]; Бар инде өйгә йитмәсдән әwwәл балаңны күрүрсән [КШ. 51]; Тарих сәкиз йөздә рамазан айның әwwәлендә бетелде [Ибраһим хан ярлыгы], әwwәл [Кт. 68; Кт. 71]. «Сираҗ әл-кулуб» һәм «Гарәпчә-төрки-татарча сүзлек»тә илик сүзе беренче мәгънәсен биреп килә. Сүзлек авторы *әwwәл* сүзенең тәрҗемәсен *илик* сүзе белән аңлата, башка урыннарда 'первый' мәгънәсен *беренче* сүзе белән белдерә: беренче кат күк [Гс. 16] һ. б. Бу очракта (сүзлек төзүченең бер урында традицияләргә тугры калып,

сүзне берничә сүздән торган төзелмә белән аңлатканда) гадирәк, ягъни сөйләү теленә хас сүзгә мөрәҗәгать иткән дип аңлатырга мөмкин. Коръән тәфсирендә тәртип саннары төп саннарга *-(е)нҗе* аффиксы кушылып ясала: икенҗе [Кт. 68], өченҗе [Кт. 68].

Җыю саны хәзерге әдәби телдә *-ау/-әү* кушымчасы ярдәмендә ясала. Мөхәммәдъяр поэмаларында актив форма булып *-агу/-әгү* кушымчасы санала:Ултурурда бу икәгү нагяһан Килде саил кем ишеккә ул заман [ТМ. 63]; Өчәгүсе худ мәгзүл китте Аңа тиб сагынды үзенгә йитте [ТМ. ]; Берәгү балык сата ултурур йулында [ТМ. 63].

Җыю санының *-ау/-әү* кушымчасы белән ясалган очраклары да бар. Алар да Мөхәммәдъяр поэмаларында кулланыла: Килүрендә күрде икәү сүкүшүр [НС. 62]; Ир wә хатын дәнкә табмады суруб / Ул көн wә кәчәсе икәү ач торуб [ТМ. 63].

Хәзерге татар әдәби телендә җыю мәгънәсен күплек сандагы тартым кушымчалары да белдереп килә алалар. XVI гасыр язма истәлекләрендә бу очракка да мисаллар шактый күп табылды: Ғариф булуб икемез ил йығмазмыз диделәр [7]; Ана уғыл – икеси бер хөжрәгә керделәр [7]; Түртүсе бу тәдбир лә булды рәwан [ТМ]; Бу түртүсе һәр эш эчрә зөфнундур [14] һ.б.

Җыю саннары, башка төркемчәләргә караганда, мөстәкыйльрәк урында торалар. Аларда предметлык төшенчәсе зуррак урын тота: Килүрендә күрде икәү сүкүшүр [ТМ. 62].

Бүлем саннары саннар тартык авазга тәмамланса – *-ар/-әр,* сузыкларга беткәндә, *-шар/-шәр* кушымчалары ялганып ясала. Берәр әлендә берәр әбрик ула, гәүһәрдән / Берәр әлендә берәр айағ ула җәүһәрдән.

Бу – XVI гасырга караган чыганаклардан гарәпчә-төркичә сүзлектә дә шулай. Тәрҗемәдә, ягъни аңлатмада сан ике тапкыр кабатлана, ягъни икешәр икешәр, дүрдәр дүрдәр дип языла. Бу, мөгаен, кабатлау мәгънәсе бирү өчен шулай кулланыла. Өмми Камал шигырьләрендә кызыклы вариант очрый: Кәрәк ун мәнзилдә дүрт дүрт әрмәған [ӨК.47]. Бүлем саны төп сан кабатланып ясала.

Чама саннары ясый торган *-лап* кушымчасы бу чор язма истәлекләрендә очрамады.

Саннарның кулланылу үзенчәлекләренә килгәндә, алар – төрле. Истәлекләрдә файдаланылган саннар билгеле бер вазифа башкара. Әдәби әсәрләрдә еш кына ислам, Коръән тәгълиматы белән бәйле саннар (1, 2, 3, 4, 7, 9, 40, 100) очрый:

Йите дүзәх утыдин азад қыл [ТМ. 64].

Ул ғарешдә булды қылды мөнәҗәт әнәбәте,
Күрде туқыз күк сәкез оҗмах йиде там [ӨК. 67].
Һәм йиде мусхафең аны үгәр һәр айәте [ӨК. 68].

Мәсәлән, Өмми Камалның «Кырык әрмәган» әсәрендә *дүрт*, *қырық* саннары нәкъ шулай:

Кәлдүк имди кирү мизанда дәхи
һәм кәрәк дүрт әрмәгән анда дәхи [ӨК. 47].
Бәс үлүмен деләйән шәхесә ғайан
кәрәк ун мәнзилдә дүрт әрмәған [ӨК. 47].
Хәрәм ғасиан бу Камал Өммидә чук
Ул қырық әрмәгәндән бере йуқ [ӨК. 51].

Истәлекләрдә күп саннар, гомумән, күплекне белдерә. Бигрәк тә *йөз*, *мең* саннары бу максаттан актив кулланыла:

Рухына йөз бең тәхийәт вә сәлам [17:51].
Күрмәсә ул ай йөзен бер ләхзә шаһ,
Төшәр ирди җаныңа йөз дәрди аһ [ТМ. 52].
Бер заман мең төрлүк утға йакмаңыз,
Бәргөзин бу хәстә хатрен сақлаңыз [НС. 52].
Бу рәсүлнең рухына йөз мең сәлам [18: 293].

Саннар тотрыклы сүзтезмәләр, мәкаль-әйтемнәр, тапкыр сүзләр составында да килә:

Берне қылсаң, береңә ун алгайсән,
Унны бирсәң, уныға йөз алғайсән [ТМ. 50].
Теләген табмагай һәргиз бәд эндиш.
Һәр ни сагынса – кәлүр үзенә биш [ТМ. 50].

Димәк, XVI гасыр язма истәлекләрендә саннар күп кулланыла, язылышларында тарихи тәңгәллекләр чагылыш таба, мәгънәви функцияләре төрле.

### 3.5. Алмашлык

Мөхәммәдъяр поэмаларында I һәм II зат алмашлыклары *мән, сән* формаларында килә. «Нуры содур» поэмасында бер урында гына *мин* варианты кулланылган. Аларның килеш белән төрләнешенә мисаллар: Балық алыб, биргел сән мәңа утун [НС. 47], Имди мәндин алғыл аны уш сән уң [НС. 46], Эwенә барыб ашағыл аны бөтүн [НС. 47], Сәндин үзгә һич кеше алмас аны [НС. 47], Лотф итеб, андин хәлас иткел мәне [НС. 47], Қылды хәммал аның сүзени қәбул [НС. 47]. I зат алмашлыгы хайваннарга бәйле дә кулланыла: Бичин әйде: «Фәлән ат-

лығ тағда *мән*, Барсаң аңа, ул тағ эчендә бағда мән» [ТМ. 56а], Қаплан әйде: «Мән (дә) һәм ул тигрәдә Бер биркәдә булурмән, и кәдхода...» [ТМ. 56а], Йылан әйде: «Бу ил хисарында мән, Анда барсаң, тапук қоллуқ иткәймән» [ТМ. 56а].

Кол Шәриф иҗатында *мән* төп форма булса да, *бән* варианты да кулланыла: Мән әйтәйен бифәрман [КШ. 44]; Мән шикәстә ғәрибнең халин бер дәм сурмадың [КШ. 46]; мән ғәрибне, җан балам, имди маиб қылдың» диб [КШ. 48]; гөнаһыңдин бән үтдем, белгел, ходай үтмәде [КШ. 49]; айрулуб мән баламдин, имди қайа барайсы [КШ. 50]; ғариф мән дип күп шәйех дөнйа йиғыб йатубдыр [КШ. 51].

Өмми Камал иҗатында бары тик *бән* варианты гына кулланыла. Әгәр бән дидүгеме дота белсәм [ӨК. 73]; Йулында сән ғәнинең бән фәкирең [ӨК. 73]; Һәм әйдә разыймы сез вәлиләрем бәндән [ӨК. 56]; Бәне зыйарәт идәчеләрем дустларым [ӨК. 54]; Бәнем бәғде адыма ғәйәр сығмаз [ӨК. 35]. I зат берлек сандагы *бән* алмашлыгы юнәлеш килешендәге *бәңа* формасын ала, иялек килешендәге – *бәнем* формасын: Комулар илтәчәк анда әрмәган / төхфәм ум бонлар дорур бәнем һаман [ӨК. 46]; бәңа бер дәстүр вир әй шәмс ру / кем үлүмем деләлүм андан кирү [ӨК. 46].

«Сираж әл-қулуб» әсәрендә I зат берлек сан алмашлыгы من – *мән* һәм مين – *мин* вариантларында бирелгән. Аны Ә. Нәҗип әдәби традициянең нәтиҗәсе һәм сөйләмә телнең кулланылышы белән аңлата [Наджип, 1989, с. 158]

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлегендә I һәм II зат берлек сан алмашлыклары кулланылмаган.

Мөхәммәдъяр иҗатында II зат берлек сан алмашлыгы *сән* формасында килә һәм тулы төрләнеш парадигмасын күрәбез: Сүз эчендә *сән* йөзүмни ақ қыл [ТМ. 62а]; *Сәнең* тәк дошман урыны дар булгай [ТМ. 48а]; Җәннәт эчрә бостан қылғай *сәнең* чөн [ТМ. 62а]; Йарлыкаб тәкре биргәй сәңа* тәүфиқ [ТМ. 67б]; Қызга әйде: «Мән *сәне* никах берлә алайым [ТМ. 61б]; *Сәндин* үзгә йуқ ирүр мәңа пәнаһ [ТМ. 61а]; Кеше *сәндин* күңүл өзсә, *сән* өзмәгел [ТМ. 60а]; Булса *сәндә* ғәқл-у данеш, хирәдмәнд [ТМ. 59б]. Мөхәммәдъяр поэмаларында автор, кешеләрдән тыш, хайваннарга, язмышына, күңеленә *син* дип мөрәҗәгать итә. Шагыйрь күңелен борчу алган вакытларда аңа эндәшә, аны тынычландыра, язмышы белән гәп кора: И фәләк, сән худ ирүрсән бивафа / Табмадым бәргөзин *сәндин* сафа [ТМ. 54а], Нәчә үртәрсән, – дидем, – *сән*, и күңүл, / қуй мәне үз халемә, мәндин түңүл [ТМ. 44а]. Бу чорга караган башка истәлекләрдә дә *сән* формасы урын ала.

Өмми Камал шигырьләрендә *сән, син* вариантлары кулланыла: Мөҗтаба wә мөқтада / хақичүн қамумызы *сән* йарлыка [ӨК. 51]; кем йазуқлардан дүнә *сән* сән табиб [ӨК. 47]; чөн хәбәр wирдүк нәбидән *сәңа* без [ӨК. 51]; кәлүк имди шунлары қыл *син* фикер [ӨК. 57]; һәм бере дөн намзыдур *сәнең* / ғишықилә қыл кем бихмәт ула *синең* [ӨК. 48]; *сән* деләмәдин дәхи *сәңа* кәлүр [ӨК. 46].

Сәхибгәрәй хан һәм Ибраһим хан ярлыкларында ул кулланылмый.

III зат берлек сан *ул* алмашлыгы Мөхәммәдъяр әсәрләрендә: Ибне Әсғәд ләшкәрени қырды *ул* [НС. 60], Һәр ки тотты телени қотулды *ул* [НС. 58], Эwенә барыб ашағыл *аны* бөтүн [НС. 58], Сәндин үзгә һич кеше алмас *аны* [НС. 47], Лотф итеб, *андин* хәлас иткел мәне [НС. 47], Қылды хәммал *аның* сүзени қәбул [НС. 47], Бетмеш ирди *анда* бер тағ, аңлағыл [НС. 63], Йети иқлимни *аңа* биргел өлүш [НС. 62].

Өмми Камал шигырьләрендә: Һәм бел әгяһ *ул* кә ризwаның дәхи / әрмәғәне wар дорур *аның* дәхи [ӨК. 47]; Һәм кәрәк дүрт әрмәғән *аңа* шәриф / ишетимди ул нәләрдүр әй хәриф [ӨК. 50]; Чөнкә қол сәүгән белүбән қыла аһ / қуртара қурқурарындан *аны* шаһ [ӨК. 49]; Бәңа бер дәстүр wир әй шәмсру кем үлүмен деләлүм *андан* кирү [ӨК. 46].

Юнәлеш килештә *аңар* формасы очрый: анар тийеш йукдур [П. 48-10].

*Без* һәм *сез* алмашлыклары тикшерелә торган истәлекләрдә мәгънәләре ягыннан хәзерге татар әдәби теленнән аерылмыйлар. Мөхәммәдъяр иҗатында I һәм II зат күплек сан алмашлыкларының килеш белән төрләнешенә *без, безләр, безем, безгә, безә, безне, бездин*; *сез, сезләр, сезнең, сезгә, сезә, сезне, сездин, сездә* очракларына мисаллар теркәлгән: Дөнйа *без* буланчә күрүнмәз күзенә [НС. 66а]; Ғәфу итеб *бездин* кичүргел бу заман [НС. 61а], Сән *безем* йаманымызға бақмағыл [НС. 61а], Қәһр уты берлә *безни* йақмағыл [НС. 61а], Қәһр қылма *безгә* сән, и намдар [НС. 61а], Рәхмәтеңдин *безни* қайтарма қоруғ [НС. 64а]. Шул рәвешле, Мөхәммәдъяр поэмаларында *без* алмашлыгының иялек килешендә угыз кушымчасы килә, алмашлыкларның килеш белән төрләнешендә кушымчаларның угыз тибы да урын ала. Мәсәлән, юнәлеш килешендә *-гә* – 17, *-ә* кушымчасы – 3 тапкыр, *-не* – 3 мәртәбә, *-и* аффиксы бер урында кулланыла:

*Безләр* бер урында һәм *сезләр* өч тапкыр «Төхфәи мәрдан» поэмасында кулланыла: Wафасыз кеше күрдүк безләр аны [ТМ. 56а]; Мән

ирүрмән сезләр ара бичара [ТМ. 47а]. Биргәм сезләр җанына зәүқ wә сафа, Дидарымны күрсәтеб, қылғам wафа [ТМ. 51а].

Мөхәммәдъяр поэмаларында дәүләт җитәкчеләренә сүз кушканда *син, сез* алмашлыкларының кулланылышы кызыклы. «Күплек санда килгән икенче зат алмашлыгы тыңлаучы затларның күплеген күрсәтә һәм, ихтирам белдергәндә, икенче зат берлек сан мәгънәсендә кулланыла» [Тумашева, 1978, б. 95]. *Сез* алмашлыгы поэмаларда, нигездә, затларның күплеген белдерә:

Әйде: *И ахмаклар*, *сез* орушмаң, / Бер дәнке өчен ата-ана сүгешмәң [ТМ62б].

Алмашлыкның икенче мәгънәсе Мөхәммәдъяр әсәрләрендә шулай ук урын ала [Кадирова, 2012]. Вәзирләр шаһка мөрәҗәгать иткәндә күп урында *сез* варианты килә: Ул ғәкрәб тиккәненә түзмәдин / *Сезгә* сабрым барын күргүзмәдин [НС. 54 а].

Шаһ вәзиргә *син* ди: *Сәне* ғәкрәб ул заман тиккәндә үк / Нә сәбәбдин чықмадың *сән* анда ук [НС. 54 а].

Вәзирләр шаһка эндәшкәндә һәр очракта да *сез* алмашлыгын кулланмый. «Төхфә-и мәрдан» поэмасында юлбасарлар турында хикәят бар. Анда вәзир ил башлыгыннан юлбасарлар арасындагы бер әсир егетне азат итүне сорый: Диде: *И падишаһ һәр ду милләт*, / Мәнем җанымға салғыл төрлүк миннәт / *Сәнең* чөн фида булсун қолың җаны [ТМ. 66а]. Бу – бердәнбер очрак.

Поэмаларда хәммал, утынчы, балыкчы, карт һәм яшь егет, ир һәм хатын, егет белән кыз бер-берсенә *син* дип эндәшәләр. Гади гарәп кешесе дә шаһка *син* дип мөрәҗәгать итә: Кем сәңа кэлдем, *хәлифә*, бу заман [Н.с.49а].

Эндәш сүзләр янында кулланылган *син*, *сез* алмашлыкларыннан *сез* дип эндәшү югары дәрәҗәдәге кешеләр арасында күзәтелгән: вәзирләр шаһларга *сез* дип мөрәҗәгать иткәннәр.

Аллага, Мөхәммәд пәйгамбәргә эндәшү поэмаларда зур урын алып тора. Аллага аның сыйфатларын атап һәм *сән* дип эндәшү актив: Әйде: И қөдрәт изәсе, кардигәр / Тәүбә кылдым, *сән* кәчүр, пәрwәдигәр [ТМ53б]. Бу башка истәлекләрдә дә, мәсәлән, Мөхәммәд Әминнең «Гыйкаб» шигырендә, Өмми Камал иҗатында да шулай: Йә илаһи, әйлә ул бәндәңне сән [Тәварихы Болгария, б. 60], Илаһи өстүмезә рәхмәтең сәч / Сәңа лайық қани ағыз wә делсүз [ӨК. 41].

| Килешләр | Өмми Камал әсәрләрендә | Мисал |
|---|---|---|
| Баш килеш | без | Чөн хәбәр wирдүк нәбидән сәңа без [ӨК. 51] |
| Иялек килеш | безем, безин | Ул безә бездән йакындур безинчүн андан йырак [ӨК. 68]<br>Ул ниғмәт кәчмәз ди безем хәтеремездән [ӨК. 56] |
| Юнәлеш килеше | безә<br>безгә | Бал шәкәрдән әмлах ширин кәлүр безә [ӨК. 67]<br>Дөнйа ниғмәтләрене ул wирде безгә [ӨК. 63] |
| Төшем килеше | безе | Мәгәр ул мөршид камил қыла безе аңа wасыйл [ӨК. 35] |
| Чыгыш килеше | бездән,<br>беземдән | Хушнуд ул анлардан һәм бездән қаму [ӨК. 35]<br>Wәли һич күрмәде бонлар беземдән [ӨК. 73] |
| Урын-вакыт килеше | бездә<br>безләрдә | Бездә хәрам, хаталар биғәдәд [ӨК. 35]<br>Бу йулда wар делем пәрдә нә қылалум кә безләрдә [ӨК, 64] |

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлегендә I зат күплек сан алмашлыгының بیزلار – *безләр* варианты очрый [ЗвК. 64а].

Казан ханлыгы чоры истәлекләрендә III зат күплек сан *анлар* һәм *алар* (хәзерге татар әдәби теле формасы) вариантларында килә, әмма *анлар* формасы кулланылыш ешлыгы ягыннан активрак.

Мөхәммәдъяр әсәрләрендә III зат күплек сан алмашлыгы *анлар* һәм *алар* вариантларында теркәлгән: Үлтүрүб *аларны* ғаси булдилар [ТМ. 66б]; Чықарыб данкене бирде *аларға* [ТМ. 62б]; *Аларның* бу тариқә мәғишәтләри [ТМ. 62б]; *Анлар* илә бергә булғандур йәқин [ТМ. 66]; Шәмғун *анлардин* ойалыб ул заман [НС. 56]. Бу алмашлыкларның төрләнешендә бары бер очракта гына угыз формасы очрады.

III зат күплек санда *анлар* формасы бик актив: һайбәтилә кәләчәк анлар сәңа / һәм кәрәк дүрт әрмәган анда аңа [ӨК. 48].

«Сираб әл-кулуб» әсәрендә *алар*, *анлар*, *улар* вариантлары кулланыла [Наджип,1989, с. 158].

III зат күплек сан алмашлыгы «Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлегендә бары тик *алар* формасында гына килә һәм эңгәмәгә катнашмаган затларны белдерә: آلار – алар [ЗвК. 61 b], الارنی – аларны [ЗвК. 61а].

Сәхибгәрәй хан ярлыгында урын алган зат алмашлыклары күп түгел: Безгә wә безнең оруғымызға доға wә алқыш қылсынлар.

Шулай да *мин, безнең* формалары бу ярлыкта шул чор халык сөйләм теленә хас формалар урын алганлыгын күрсәтә.

**Күрсәтү алмашлыклары.** Өйрәнелә торган истәлекләрдә *бу*, *ул*, *у*, *ошбу*, *ушал*, *әһле*, *шул*, *шу* кебек күрсәтү алмашлыклары урын ала.

Мөхәммәдъяр поэмаларында *ул* күрсәтү алмашлыгы гаять актив кулланылышка ия: Ул қуй арыды, ғәқибәт тотдуң аны [НС. 45а],Ул борунғи рузгярда, и йегет [НС. 46], Бер хәммал бар ирди, хуш ишет, Ул йегет мескин ойалыб тик торур [НС. 61 а], Кереб қаплан ул қызины үлтүрүб [ТМ. 56б], Ул шәһәрдин кәчәрендә кем һаман Йадиға килде Зәргәр ул заман [ТМ. 56б]. Мөхәммәдъярның «Нәсыйхәт» шигырендә *ул* алмашлыгы өч урында килә, әмма бер очракта *у* рәвешендә бирелә: У хәсрәтдин дәхи башы ағармыш [НС. 309].

*Ул* алмашлыгы – поэмаларда иң күп кулланылган сүз (285 тапкыр), әмма бер генә урында да кыскартылган варианты очрамады. Кыскартылган очракка мисаллар Өмми Камал иҗатында күп: У тапасының бере алтун ула бере көмүш [ӨК. 55]; У тапасыларда ула шул тәғәмләр кә аны [ӨК. 55].

*Бу* алмашлыгы да әлеге автор поэмаларында еш файдаланыла: Бу қаплан қылды, күр, мәрданәлық [ТМ. 56б], Бу күңүл қуймас мәне аһ wә аһ, Бу күңүлдин сақла мәне, и илаһ [ТМ. 54б], Мон бигин эш адәмигә төшмәгәй / Мән тиггән утға кеши пешмәгәй [ТМ. 54б], Бақ ни эшләр бу фәләк гәрдешенә [ТМ. 56б], Бер заман мең төрлүк утға йақмаңыз, Бәргәзин бу хәстә хатрен сақлаңыз [ТМ. 56б], Шаһ үзе бу вәғдәне белүр иди, Ошбу эшнең чарәсын қылур иди [ТМ. 52б].

Килеш белән төрләнгәндә, бары тик *м* варианты гына килә: Шаһ ди: «И қызым, бер йылга *монда* қарар» [ТМ. 53а], *Мондин* үзгә безгә йахшы йуқ һаман [ТМ. 65б], Шаһ күрүр (һәм) һич кеши күрмәс *мони*, Бу ғәҗәб сер, һич кеши белмәс *мони* [ТМ. 52а], Ишетеб Гөлруй бичарә, мескин / Монуң бу сүзендин булды ғәмгин [ТМ. 48а], Ики кемсә ултурур *монлар* ара [ТМ. 52а], Шаһ булуб *монлар* эшендин сәһемнак [ТМ. 52а].

Бу әсәрләрдә *ошбу* алмашлыгы да кулланыла, әмма статистик тикшерү аның аз санда булуын күрсәтә: Ошбу Зәргәр йаман йәкҗәһәт иде [ТМ. 57б], Җәмиғ қылдым ошбу «Төхфә-намә»ни [ТМ. 64б], Шаһ атыға бетедем ошбу китаб [НС. 56б], Ошбу диннең хәқлықына йуқ сүзем [НС. 59], Ошбу ирди мәғнәси, әйтәйем сәңа [НС. 58], Ишетеңез ошбу сүзни хасс-wә ғәм [НС. 46].

«Нуры содур» поэмасында берничә очракта автор гарәп теленнән кергән *әһле* алмашлыгын куллана: Күчтиләр *әһле* йортдин анлар қәмуғ

[НС. 48]. Бу алмашлык Өмми Камал иҗатында да очрый: Әһле бәйте табгыйн әхйар өчүн [ӨК. 38].

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» әсәрендә *бу* алмашлыгы очрый: غزاة اهليغه عالمدا بو بر حسن لطافت بار [ЗвК. 60b], بو خبر مصطفوی من رمی في سبيل الله تعالى [ЗвК. 60b],بو اولومنينك خوفيدين چشمة حيوان تترايور [ЗвК. 61b],بو سببدين و هم ايتيب خان بلكه سلطان تترايور [ЗвК. 61b],ايرور بو يير هميشه دنيادا خان ابن خان شهری [ЗвК. 61b], بو يردين بولماسون هيچ سايه سی كم [ЗвК. 62a].

Өмми Камал шигырьләрендә *шул* алмашлыгы еш кулланыла: Шул кеше кем бер өчүн икедә [НС. 69]; Мостафа шул тәғәт эчрә [ӨК. 68]; Шул шәһид улан мөҗәһидләр хақы [ӨК. 39].

Шагыйрь иҗатында бу алмашлыкның борынгы *шу* варианты да актив: Шу қош биге дөшәрүз данә үзрә [НС. 74]; Дийә күтәр арадан шу пәрдә дәхи кем [НС. 56]. Аңа шу рәсемә хуш аwаз wирә аллаһ [НС. 56]. Ишедүр белүр шу кем һәр йалғузлар ишедүр [НС. 69].

Әлеге алмашлык текстларда исемләшеп, күплектә килә, тартым кушымчалары ала. Килеш белән төрләнешенә дә шигырьләрдә мисаллар күп: Шулары кем аныңла ашнәдүр [ӨК. 70]; Зи сәғәдәт тәңредән шунлара кем йарунғы көн [ӨК. 68]; кәлдүк имди шунлары кыл син фикер [ӨК. 48]; Шуларың хөрмәтичүн кем белешдүр [ӨК. 41]; Шулар һәр бере бер қоллықда эшдә [ӨК. 41]; Шулар кем дөнә ачыла қарара [ӨК. 41]; Қыш җәфада шулар кә каһәрә туш улды / Йаз сафада шулардур кә улды лотфына туш [ӨК. 8]; Күзен қашын шуны харҗанисасын [НС. 72]. Бойурды кем өмидемез шуңадур [НС. 71]. Шуны шөйлә күрүргән кирү холқың [НС. 71]. Шуның кә ғәреш көрсидән уңдур бидайәте [НС. 67].

**Сорау алмашлыклары**. Казан ханлыгы истәлекләреннән, Мөхәммәдъяр әсәрләрендә *нә/ни, кем, қайу, нимә, қайда, қайсы, қандин, қач* кебек сорау алмашлыклары урын ала. Аларга мисаллар китерү белән чикләнәбез: Бәс, ни килсә башка, бел, телдин килүр [ТМ. 57]; Нәчә тигәр ирди ғәкрәб үзени [ТМ. 53]; Кайу кеше сабыр қылса ул мөдам [ТМ. 53]; Йә қачан кем бетисә аны қәләм [НС. 62]; Җәүһәршинас әйде: «Бу қандин килде?» [ТМ. 63б]; Нәчә қурла аһ оруб [ТМ. 59а]; Ни сәбәбдин ихтийар иттең мәни [НС. 45].

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлегендә сорау алмашлыкларына мисаллар күп түгел. *Кем* алмашлыгы аерым затка күрсәтә: بو يردين بولماسون هيچ سايه سی كم [ЗвК. 62а].

Әлеге әсәрдә бу алмашлыкның кулланылу ешлыгы зур (ЗвК. 60a, 60b, 61a, 62a, 62a, 62a, 62b, 63a, 63a, 63a, 63 b, 63b, 63b, 63a, 63a, 64b, 64b) [Özyetgin, б. 383].

*Нә* алмашлыгы «Зафәрнамәи вилаяте Казан» текстында *нә/ни* вариантларында кулланыла [Özyetgin, б. 393].

«Гыйкаб» шигырендә дә *нә* формасы урын ала: Нә җавап бирүр хода қашыда ул [Тәварихы Болгария, б. 60].

Өмми Камал иҗатында сорау алмашлыкларына мисаллар гаять күп санда. *Кем* алмашлыгына мисаллар китереп үтик: Ничә кем ғәҗиз ғәиб йазуғыма [ӨК. 73]; Тәмизең wарисә кемдән кем аңла [ӨК. 72]; Нә кем кәсеб итдүңисә йаз йәйен [ӨК. 72]; Үземе күзләмә сүзем ишет кем [ӨК. 71]; Без кемез кем сәңа лаиқ әрмәғән [ӨК. 51]; Кем шәфәғәт қыла ул сәңа дәхи [ӨК. 51]; бере улдур кем қыла халес ғәмәл [ӨК.47]; Кем зинадан тәүбә қылса қортылур [ӨК. 47].

*Нә* һәм аннан ясалган алмашлыкларны бу автор иҗатында күпләп табарга була: Ничә мөәминләрнең буйнун чапарсән [ӨК. 71]; Айа, ғәфил, ничә йулдан сапарсән [ӨК. 70]; Ничәсе wасыф иде белә кем ул ғәйәте [ӨК. 69]; Ничә wасыф әйдәйем кем бу делем [ӨК. 35]; Нә қылды һәр тарафы дөрле хәлғәт буш [ӨК.8]; Кә қылыч нәснә кисмәз қын эчендә [ӨК. 72]; Нәчә кәсрәйе йотды йийде бу йир [ӨК. 72]; Нәдән кәлдүң нә сән фикер илә даим [ӨК. 71]; Бу йулда wар делем пәрдә нә қылалум кә безләрдә [ӨК. 64].

*Ничә* һәм *нәчә* вариантлары язуда чагылыш таба: نچه һәм نيچه .

Шагыйрь иҗатында борынгы *қан-* тамыры белән бәйле сорау алмашлыклары актив кулланыла: Сәйран улур ди қанда йөрүрсә аңа болут [ӨК. 66]; Қани тәғәт мәҗәл ирмәз [ӨК. 55]; Кәрбан китде қани азуқ йарақ [ӨК. 51]; Қанки адәмдә кә wар улур мөлек [ӨК. 50]; Делемездән дәлем йомшақ қани таш [ӨК. 42].

Өмми Камал текстларында әлеге алмашлыклардан тыш, *нинди, кайсы* алмашлыклары мәгънәсендә фарсы алынмасы *чу* алмашлыгы еш очрый: Чу тупрақдан йаратылды тәнемез [ӨК. 19]; Чу тула күңел уй қаранғулығилә аңа [ӨК. 57]; Чу туғры йул wарымызым күрәрләр [ӨК. 73].

Колшәриф иҗатында шулай ук *қан-* тамырлы сорау алмашлыклары кулланыла: Күзе йәшлиғ, бәғри башлиғ булмағунча булур қандин [КШ. 34]; Кәнҗе ғишқы кәрәк ирсә, алтун-көмүш чықса қандин [КШ. 34]; Қол Шәриф, атаң-анаң сәндин борынғылар қани [КШ. 29]; зари қылуб йығлайдур: «кайда ғәиб булдың ?» – диб [КШ. 48].

**Билгеләү алмашлыклары** предмет, күренеш яки төшенчәләрне берәм-берәм яисә җыеп билгеләү өчен килә. *Үз* алмашлыгы Мөхәммәдъяр иҗатында актив, һәм ул, еш кына, мөстәкыйль кулланылып, тартым кушымчалары ала: Үзләре бер хали йирдә йәшенеб [ТМ. 65б],

Наданлықдин үз башына йиткәнләр [ТМ. 60б], Хөрмәт иткел үзүңдин бер йәш олуғны [ТМ. 60а], Қылыб үзе төрлү, төрлү зарийәт [ТМ. 59а], Зәргәр үзе қылған бәласына үзе грифтар булғаны [ТМ. 55б].

*Кәнду* алмашлыгы «Төхфәи мәрдан» поэмасында ике урында очрый: Кәндү фиғлендин үзе шәрмәндә булды [ТМ. 49б], Кәндүнең дилзарлықны һөнәр белеб, үзене уртаға салыб, мәнмәнлеген күрсәтеб, Хушнәwаны хурлағаны [ТМ 49б].

Бу истәлекләрдә *худ* алмашлыгы да бар: Адәми *худ* пак ирүр, аслы шәриф [ТМ. 56б], И фәләк, сән худ ирүрсән биwафа [ТМ. 54а]. *Худ* алмашлыгы Өмми Камал, Колшәриф иҗатында да чагылыш таба: Нә ул Хак туғды кемсәдән нә худ кемсә туғар андан [ТМ. 64], Ходайымның әмредин худ без өлкән имәсбез [КШ. 47].

Казан ханлыгы чоры язма истәлекләрендә *барча, қамуғ / қаму, җөмлә, җәмиғ* алмашлыкларын, *һәр* сүзе катнашында ясалган алмашлыкларны билгеләргә мөмкин. Диде қызы: «И ходай кәрдигяр, барча серне сән белүрсән әшкяр» [ТМ. 62а]; Барчә ғәләм халқының солтаны сән [ТМ. 51 б]; Һәр кем уқуб, маңа доға қылса [ТМ. 64 б]; Барчамызның серредин агяһ сән [ТМ. 64 b], Җөмлә мөшкилләрне ул қылды хал [ТМ.]; җөмлә йалғандур сүзүң [ТМ. 58б]; Олуғ мән, димә, олуғ улдур – йаратқан, / Җәмиғ мәхлүқ ирүрмез җөмлә йәксан [НС. 46б]; Ирүрсән җөмлә мәзлумләр пәнаһи [ТМ. 43а]; Җәмиғ мәхлүқ ирүрмез җөмлә йәксан [ТМ. 46б]; Кем җәннәт эчендә, и дин олуғы / ғәнҗ, дәүләт, рәнҗ, михнәт – қәмуғы [НС. 46б]; Тел күни булса, күнүлүр әл, азақ / Күни булур барчасы бу күз, қолак [Н.с. 57]; Иғри булса тел, – қәмуғы игелүр [НС. 57]; И қәмуғ ханлар ичрә намдар [НС. 65]; Хәзрәтендин теләнү килдүк қәмуғ [НС. 64]; Йите иқлимдә қәмуғ ханлар ханы [НС. 61]; Хәқ тәғәлә һәр эшкә қадир ирүр [ТМ. 57 б]; ул утлуғ йәдрәләр кичәләр шәһәр эчендә һәр йиргә кем төшәр ирде [ЗвК. 63а], барчасыны йиргә төште тийү [ЗвК. 63а], һәрбер йәдрә ташы [ЗвК. 63b], Каму талиб аны сөйләр дөне көндүз [ӨК. 64]; Бу каму мөлек Рум Чин эчендә [ӨК. 72]; Қамусын сақла зинһар улма хайн [ӨК. 74].

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» кулъязмасында *һәркем* башка истәлекләрдән аермалы языла: هركيم [ЗвК. 60b], [ЗвК. 62а]. Башка очракларның язылышына да мисаллар: *һәрбер* هربرى [ЗвК. 62а], [ЗвК. 63а]; بارچاسينى – барчасыны [ЗвК. 63а]; آوزى – үзе: [ЗвК. 61b], اوزلارين [ЗвК. 62b].

Юклык алмашлыкларыннан һич алмашлыгы XV–XVI гасыр язма истәлекләрендә еш кулланыла. Йебе череген белде, һич кемсә алмады

[ТМ. 63б]; Алғыл нанны һич кем ирсә белмәсүн [ТМ. 60б]; Аның имен һич утачы белмәгәй [ТМ. 57б]; Мәңа сән қылмадың һичбер wафа [ТМ. 54а] кебек мисалларга Мөхәммәдъяр әсәрләреннән тагын да өстәп булыр иде. Өмми Камал иҗатында да алар шактый: Кем йаланчының һич улмаз хөрмәте / һич сүзенә кемсә қылмаз рәғбәте [ӨК. 48] Җөмләсене сәwәгә йуқдур һич кеми [ӨК. 51]; Нә һич кемсәләрнең ул хатерендән кәчде [ӨК. 51]; Аны күрүб кәтүрмәйә һич бере тәқәт [ӨК. 56]; Бу дәрдлү күңлемең һич уңалмаз җәрәхәте [ӨК. 67]; Кә бәңа һич мәдәд йуқ көндүземдән [ӨК. 73], Бизәнде биңзады һәр бер дөккән бәззазә [ӨК. 8].

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» хезмәтендә юклык алмашлыкларыннан *һичкем* алмашлыгы очрый: هيچ كيم ايرسانينك عرصه سى يوق ايردى [ЗвК. 63а].

Шул рәвешле, истәлекләрдә барлык төр алмашлыклар да актив кулланылган. Бу чор язма истәлекләрендә зат алмашлыкларының, кыпчак вариантлары өстенлек иткән хәлдә, угыз һәм уйгыр формалары да урын ала, борынгы төрки алмашлыклар да очрый.

### 3.6. Фигыль

Фигыль – иң продуктив кулланылган сүз төркеме. Эшнең үтәлү-үтәлмәвенә карап, фигыльләр Мөхәммәдъяр поэмаларында барлык яки юклык формаларында киләләр. Аларның формалашуында хәзерге әдәби телдән аерма юк диярлек.

### 3.6.1. Затланышлы фигыль формалары

Мөхәммәдъяр поэмаларында фигыльнең затланышлы төрләре өч төркемчә белән күрсәтелгән: боеру-теләк, шарт һәм хикәя фигыльләр.

*Хикәя фигыль.* XV–XVI гасыр язма әдәби телендә үткән заман хикәя фигыль нигезенә *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалары ялгану ярдәмендә ясала, һәм ул, хәзерге татар телендәге кебек үк, сөйләү моментыннан алда үтәлгән конкрет эш-хәлләрне белдерә. Мисалларны һәр төр стильдәге үрнәкләрдән күпләп китерергә мөмкин. Мәсәлән, Мөхәммәдъярның «Нуры содур» поэмасындагы икенче бабка китерелгән 42 юллык хикәяттә 25 үрнәк бар. Күб йөкүрдүң, һич арыб ултурмадуң [НС. 45]; Арығаныңны кешегә белдүрмәдүң [НС. 45]; Ул куй арыды , ғәқибәт тотдуң аны [НС. 45]; Рәхим қылыб ул дәм уруттың аны [НС. 45]; Әйдең аңа: и мөбарәк җанwар [НС. 45]; Күб йөгүрдүң сән қачыб, ардуң мәгәр [НС. 45].

Истәлекләрдән бу заман формасының барлык затларына очраклар теркәлгән: Үзе чөн кем бирде сәңа қызыни [НС. 45], Сән қәбул қылдың үзеңә сүзени [НС. 45]; Чөн бу сүзе дыңлады фәхри җиһан / Ул ара дүнде әйтде әй фәлән [ӨК.46]; Кәлдүк имди кирү ризwанкярына [ӨК. 50]; Күчтиләр әһле йортдин анлар қәмуғ [НС. 48]; Тигмә йару бардылар кечек, олуғ [НС. 48]; Кешеләрнең үзләренә ни йахшысы булғай диб, ал нишанлығ йарлығ бирелде [Сәхибгәрәй хан ярлыгы]; азат тархан булсун тидүк [Ибраһим хан ярлыгы]; Хаҗи Курбан хафиз бетелде [Ибраһим хан ярлыгы].

Бу кушымчаның әлеге чор истәлекләрендә саңгыраулыкта ярашкан очраклары да бар. Алар, нигездә, Мөхәммәдъяр иҗатында күзәтелә. «Нуры содур» поэмасының соңрак күчерелгән нөсхәсендә унлап урында кушымчаның саңгырау варианты килә: qajt + dy [В нөсхәсе], то в qajt+ty [Г нөсхәсе]; tutdy [В нөсхәсе] – tutty [Г нөсхәсе] (ике урында); jatdy – jatty; išetde – išette, išetdelär – išettelär; eš itdelär – eš ittelär [Кадирова, 2014, с. 83]. Мәсәлән, Күчтиләр әһле йортдин анлар қәмуғ [НС. 48]. Г кульязмасы XVIII гасыр ахырында күчерелгән нөсхә булганлыктан, без бу формалар соңгырак чорда кертелгән үзгәрешләр дип саныйбыз. Башка истәлекләрдә кушымчаның яңгырау варианты кулланыла: йақды [ӨК. 46]; ашды [ӨК. 73]; йотды [ӨК. 72]; очдылар [ӨК. 35]; басды [ӨК. 35]; дөздүң [Кт. 48]; итдүң [Кт. 48]; йаратды [Кт. 24].

I зат берлектә һәм күплектә, II зат берлектә кушымчаның һәм иренләшкән, һәм иренләшмәгән вариантлары кулланыла, ә III затта иренләшкән формалар гына урын ала: jör + dem (2); jökür + düŋ (1); kür + dem (5); + dük (1); + düŋ (2); + düŋez (1); to + duŋ (1); + dy (4); + ty (6); + tuŋyz (1) [6]; tidük, sojurğaduq [Кадирова, 2001, с. 148].

Әлеге форманың «Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлегендә дә еш кулланылуын әлеге мисаллар күрсәтә: قرشو توردیلر – каршы тордылар [ЗвК. 63а], توشتی – төште [ЗвК. 63а], مشغول بولدی لار – мәшгуль булдылар [ЗвК. 64а], بولدی– булды [ЗвК. 64а], قیردی لار – кырдылар [ЗвК. 64а], بولوب قایتتی – булуб кайтты [ЗвК. 63b].

*-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы форманың Мөхәммәдъярның «Төхфәи мәрдан» поэмасында нәтиҗәле үткән заман мәгънәсендә кулланылган очрагы та теркәлгән: Барча хәлендин хәбәр биреб әйде ирсә, хатыны йахшы қылдың тиде [ТМ. 62б] [Бурганова, 1980, с. 92].

Мөхәммәдъяр, Колшәриф әсәрләрендә шулай ук үткән заманны белдерү өчен *-ыб/-еб* кушымчасы да очрый: Уқуғанны ишүткән мо-

радиға йитүбдер [КШ. 50]; Ишетебмез: қатуқның йоғы қалур, түкүлсә [КШ. 50]; Ошбу михнәт кем килебдер җанына [ТМ. 55а]; Табыбдур зинәт, табмады ноқсан [НС. 41б].

XV–XVI гасыр истәлекләрендә үткәндә булып узган эш-хәлне бирү өчен *-мыш/-меш* кушымчасы да файдаланыла, әмма бу чор өчен сирәк кулланылыштагы формалар рәтенә керә: Күрдем анда кем йатур бер кач җәwан, / Сач, сақаллары таранмыш, тазә уш [НС. 51], Шағир улмышлар барча кечек һәм олуғ [ТМ. 44б]; Йахшы қылдың биреб, Алмыш сән балық [ТМ. 63а].

Өмми Камал әсәрләрендә, Коръән тәфсирендә һәм «Сираҗ әлқулуб»тә [Наджип, 1989, с. 168] *-мыш/-меш* кушымчасы нәтиҗәле үткән заманның төп формасы булып тора, әмма еш кулланылмый: Назлы чынар толны қысыб қочмыш / буйнина хамаил, билинә қәмәр ормыш [ӨК. 52]; бәнәфшә кунилеб буйнины икмеш / нәргиз сөйенеб назилә күзен қысмыш [ӨК. 52]; Мәймүн мөршид улмыш аның хәй хәләмилә [ӨК. 67]; Раwи қылмышдур риwайат хуш малих [ӨК. 42]; Рәхмәтеңә ки сусамышдур суар [ӨК. 40]; Қоръәнилә хөкем улунмышдур [Кт. 8]; Даwуд аңа дидеки: Хақиқәтә бу қәрдәшүң сәңа золм итмеш [Кт. 97].

*-ган/-гән* кушымчасы да үткән заман хикәя фигыль функциясендә сирәк кулланыла: Тәңренең һәйбәтендин нагәһан Заһид мескин сусаған ул заман [НС. 64]; Бел соңыны бақмайын эш иткәннәр / Наданлықдин үз башына йиткәнләр [ТМ. 60б]; Анлар илә бергә булғандыр йақын [ТМ. 66а].

XV–XVI гасыр истәлекләрендә үткән заманның аналитик формалары бик актив. Күптән үткән заман хикәя фигыльнең грамматик формасы *-мыш + ирде:* Аты ирди Әбусәғид, аңла аны, Хикәм берлә тотмыш ирде дөнйаны [НС. 53]; Күрде бер күл: эче балчық, су тулуғ, Сусамыш ирде ул ғәрәб бигөман [НС. 48]; Булмыш ирде балықындин ул бизар [ТМ. 63а]; Әйде кем булғай бу йир җәннәт мәгәр Кем ишетмеш ирдем андин мән хәбәр [НС. 49]; Йөз мең алтун ирди аның қиммәти, Йатмыш ирде – кубты хәммал дәүләти [НС. 47]. Мисалларда бу форма үткәндәге икенче бер эштән алда булган эш-хәлләрне белдерә.

Алдагы гасыр язма истәлекләрендә үк актив кулланылып килгән *-ыр ирде* формасы без өйрәнә торган чорда да активлыгын югалтмый. Мөхәммәдъяр поэмаларында бу кушымча күбрәк III зат берлек санда кулланыла: Қыйаға барыб, кәлтүрүр ирде утун Арбасы берлә күтәрүб тигмә көн [НС. 46]; Хуш аwазы берлә ғәрзен итәрди, шаһ һәм хуш аwазын сәwәрди [ТМ. 63а]; Сатар ирде ике данкигә ани, Ул тәсәддық

қылур ирде берене [НС. 46]; Белмәс ирдиләр сөчүк суны ауға, Суны сурса қанур ирдиләр уға [НС. 48б], کلتورور ایردی لار – кәлтүрүр ирделәр [ЗвК. 61а]. Колшәриф кыйссасында *-ур ирмеш* формасы бар: Солтан Хөбби ишүтсә, булур ирмеш мәдәдкәр [КШ. 50].

Тикшерелә торган чорның күпчелек язма истәлекләрендә *-гай ирде /-гәй ирде* кушымчалары да кулланыла: Ул дәм эчрә күб доға қылғай ирдем, Йарылықым сүзени айғай ирдем [НС. 65]; Кылғай ирде йарлықаб мәңа нәзар, Кәйра булғай ирде эшем мөғтәбәр [НС. 65]; Тигәй ирде теләкем барча рәwан. Кем ғинайәт қылса ул шаһи җәһан [НС. 45]; دیکای ایردینکیز – дигәй ирдеңез [ЗвК. 63а], اوچقونلارنی خیال قیلغای ایردینکیز – очқунларны хыйал қылғай ирдеңез [ЗвК. 63а].

Хәзерге-киләчәк заманның *-ыр/-ер, -ур/ -үр* кушымчасы Казан ханлыгы чоры язма истәлекләрендә киң таралыш алган. Бу кушымча сөйләм вакытыннан соң булачак эш-хәлне дә белдереп килә. Мисаллар: «Булмас иман кемдә булмаса хәйа», Бу хәдис ирүр кем әйде Мостафа [НС. 48]; Кем ойатсыз кешедин килүр йаман [НС. 48]; Һич ойалмас, тигүрүр илгә зийан [НС. 48]; Гәр ту күңүл берлә ул тәүбә қылур, / Хақ қатында ул гөнаһларын йолур [НС. 48]; Һәр кем ирсәни ойалтмас ул кеши, / Даимән лотф wә кәрам булур эши [НС. 48]; Ишетебмез қатуқның йоғы қалур [КШ. 50]; Фөрйад қылуб йығлайдур Ходайына сәнасин [КШ. 48]; Олуғ ғомер дәрйасын қырық йылғача ағузур [КШ. 49]; Уқур сабақ мазидан wирүрләр гөш / Қамусы дәлү деленчә үгәрләр аллаһи [ӨК. 8]; Белүрмез чәхрәләрдән [ӨК. 73]; Йөрүрсән дәртенүб шөһрәт қылайын [ӨК. 72]; Бу нәснәдән ки анлар wасф идәрләр, пәс боларә тәүфиқ, һидайәт wирелмәз [Кт. 119].

Өмми Камал иҗатында кушымчаның иренләшкән варианты актив: Ишедүр белүр шу кем һәр йалғузлар ишедүр [ӨК. 69]; Дөшәр дүкәнләр эченә, йатур бераз биһуш [ӨК. 8]; Бал шикәрдән әмлах ширин кәлүр безә [ӨК. 67].

Кушымчаның I зат берлек санда *-мән, -мен, -мын/-ам* күрсәткечләре очрый, юклыкта *-н* формасы да кулланыла: Мөҗаwир ирүрмән бәси булуб зар [НС. 48]; Сездин уқ ирүр – белүрмән дәрманым [НС. 56]; Бән белүрәм шул нәснәйе [Кт.115].

Юклык формасы *-мас/-мәс, -маз/-мәз* кушымчалары белән ясала: Һәр кем ул куркса, ойалса тәңредин, Бер сәғәт хали булмас әмредин [НС. 48]; Қайу кем ирсә ойалса тәңредин, / Ни бойурса чықмаз аның әмредин [НС. 48]; Барча йирдә Хақны ул хазир белүр, / Һич йаман эш

қылмаз, үзе ойалур [НС. 47]; Қалмаз илдә фетнә wә золм һаман [НС. 42]; Кем йаланчының һич улмаз хөрмәте, Һич сүзенә кемсә қылмаз рағбәте [ӨК. 48]; Сәне кемә күрмәз [Кт. 36]; Ғаҗәбдүр кем бу дәрйа хәтеремдән ташар / тышра бу аһ-зар сызмаз [ӨК. 35].

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» текстыннан мисаллар: ظاهر بولور – заһир булур' [ЗвК. 60a], متصل تورور – мөттасил торур' [ЗвК. 60a], تترايور – тетрәйүр [ЗвК. 60a, 61b], تورور – торур [ЗвК. 62a].

Юклык формасы: بولماس – булмас [ЗвК. 61b]; تبولماس – табылмас [ЗвК. 61b], برماس – бирмәс [ЗвК. 61b].

*-ыр/-ер, -ур/-үр* формасы белән беррәттән, *-а/-ә, -й* аффиксы да очрый: Алтун көмүш чықа қандин [КШ. 35]; Тәқсирен үтенәмен сән бергә / Рәхим әйләб бағышлағыл мән зәғифә пиргә [ТМ. 57a].

Шагыйрь Өмми Камал иҗатында хәзерге заман хикәя фигыль функциясендә *-а/-ә* кушымчасының шактый актив кулланылуы игътибарга лаек. Мәсәлән, түбәндәге юлларда ул еш килә:

Фәрештәләр кәтүрәләр табақлар ул ходадин,
Кем улалар нәзүк дөшән зөбәрҗәтдән
Һәм эчләрендә ритаблар ула тулу тулу хуш,
Ғарәб деленчә ритаб тазә хөрмә дорур уш
Кә тазә сөтдән ағ, балдан ула татлурақ
Һәм улисәр тирә йағындан дәхи йомшақ
Йийәләр анда дәхи ул қалан йимешләрдән [ӨК. 54].

Шагыйрьнең иҗатында башка урыннарда да бу очракка мисаллар теркәлгән:

فرقت حسرت اودينه دوتاشوب يانه كونكل
Фәрқәт хәсрәт удина дуташуб йана күңел [ӨК.7];

دنيا آرزوسين كونكلدان اوزه سن
آخرت ديزگنلرينى دوزه سن
Дөнйа арзусин күңелдән узәсән
Ахирәт дизгәнләрине дузәсән [ӨК.46].

Хәзерге заман хикәя фигыль формасының киләчәктә булачак эшне белдереп килү очраклары да күзәтелә:

باشنكا اول بخت دولت تاجى قچان اور وله
Башыңа ул бәхет дәүләт тажы қачан үреләә [ӨК.85].

Бу чор истәлекләрендә *-адыр* формасы өч затның да кушымчалары белән кулланылган очракларга да мисаллар шактый: Күңүл әйтәр

ни кыладырмән сәңа [ТМ. 54б]; Төрлү төрлү кыладырсән ғәрдәшең [ТМ. 54 а]; Бу йула җанлулардан кемсә wармаз / Wәли җансыз кәләнләрә саладур [ӨК. 67]; Форйад кылыб йығлайдыр [КХ. 6].

*-а/-ә* кушымчалы хикәя фигыль истәлекләр телендә хәзерге заман мәгънәләрен белдерү өчен кулланылган.

*-ғай/-гәй* кушымчасы киләчәк заманны белдерүдә Мөхәммәдъяр поэмаларында актив кулланыла: Барча эшдә сабыр кылғай, и йегет / Ханға кылғай даимән үкүш доға [НС. 41]; Дөнйада қалғай бу сүзләр йадкәр [НС. 65]; Кем һәмишә ханға кылғайлар доға, Төне-көне айғай қәмуғлар сәңа [НС. 65]; Ничә кем булса җәһанда бу китаб, Ханға булғай даимән алғыш, саwаб [НС. 65]. Ул киләчәктә һичшиксез булачак эш-хәлне дә белдерә, шул ук вакытта эш-хәлнең булачагын фикер йөртү, фараз кылу төсмере белән дә әйтә. Дөнйада мән бақи қалғаймән [КШ. 32].

Киләчәк заманның *-ачақ/-әчәк* формасы Өмми Камал әсәрләрендә һәм Коръән тәфсирендә күзәтелә: Бағда һәр сәрwи чинари рәқыса қуйуб уйнадан Йирләрнең күкләре берлә суларың чыгачағдур [ӨК. 16], Соң нәфесдә ғомер қошы очачақ / Бу фәнадин ул бақайа күчәчәк [ӨК. 40].

Киләчәк заманны белдерә торган *-ачак/-әчәк* формасы үтәләчәге билгеле, шиксез эш яки хәлләрне белдерү өчен кулланыла: Һәйбәтилә кәләчәк анлар сәңа / Һәм кәрәк дүрт әрмәғән анда аңа [ӨК. 48]; Ачлыгы, усузлыгы дәфғ идәчәк [Кт. 8].

Угыз телле истәлекләрдә *-ысар/-есәр* формасы билгесез киләчәк заман мәгънәсендә килә: Бер кәдахур кем калу нәфс ачысар / бер қапудыр кем кәләнләр кәчесәр [ӨК. 46].

XV–XVI гасыр язма әдәби телендә үткән заман хикәя фигыльнең *-ды/-де* кушымчасы хәзерге татар телендә кулланылган функцияләрдә урын ала, билгеле үткән заманны белдерү өчен төп форма булып тора. Текстларда бирелештә аерым үзенчәлекләргә ия: I зат берлектә һәм күплектә, II зат берлектә кушымчаның һәм иренләшкән, һәм иренләшмәгән вариантлары кулланыла, ә III затта иренләшкән формалар гына урын ала; яңгыраулыкта һәм саңгыраулыкта сирәк яраша.

Нәтиҗәле үткән заманның *-мыш/-меш* кушымчасы төп форма булса да, аның белән беррәттән *-ган/-гән* формасы да кулланылышта икәнлеге күренә.

XV–XVI гасыр язма чыганакларда хәзерге һәм киләчәк заман формалары үткән заман кебек үк актив түгел. Истәлекләр телендә хәзергекиләчәк заман формасы *-ыр/-ер, -ур/-үр* кушымчасы белән теркәлә. XV–XVI гасыр язма әдәби телендә яңа морфологик формалар ныгый

бара. Хәзерге-киләчәк заман формасы, *-ыр/-ер* кушымчасы белән берәттән, *-а/-ә* аффиксы белән дә килә, әмма ул әле аз күләмдә очрый.

Тикшерелә торган текстларда киләчәк заман формалары шактый күп, әмма *-ғай/-гәй* кушымчасы төп форма булып тора.

Шул рәвешле, бу чор язма әдәби телендә дә хикәя фигыльгә караган грамматик формалар катнаш хәлдә кулланыла.

*Боерык һәм теләк фигыльләр.* Истәлекләрдә боеру, теләк төркемчәләренең семантикасы ачык билгеләнмәгән. Күрсәтелгән формалар боеру һәм теләкнең төрле төсмерләрен белдерәләр: өндәү, таләп итү, әмер бирү, үтенү, киңәш бирү, теләк һ.б.

I зат берлек сан *-айым/-айын* кушымчасы ярдәмендә ясала. Алар семантик яктан төрле мәгънә белдерәләр. *-айым* кушымчасы күбрәк кулланылган. Истәлектә I зат берлек сан формалары түбәндәге мәгънәләрне белдерү өчен хезмәт итәләр:

а) теләк: бер нәсихәт итәйем, қолақ сал: ийәсен сыйласаң, этенә сөяк сал [ТМ. 49а];

ә) тәкъдим төсмере белән теләү: диде: сатып қиммәтен килтерәем, сәнең эшеңне бу заман бетерәем [ТМ. 56б]; бирер ирсәң миңа, бу дәм алайым, тибрәтмәен, сәңа ақча санайым [ТМ. 63б];

б) теләк төсмере белән үтенү: қуй мәне, үз халем илә булайын, моддәғиләр сүзидин қуртулайын [ТМ. 44б];

в) янау, кисәтү: җәзаңны бирәйен, тиб, ушбу сәғат, йанып сүзләде Хушхун биғайәт [ТМ. 49а];

г) сүз бирү, вәгъдә бирү. Бу мәгънәдә *-айым/-айын* формасы хикәя фигыльнең *-р* формалы хәзерге киләчәк заманына туры килә: дидем: и күңлем, иҗазәт бир мәңа, мән тәқи ғарзым итәйем сәңа [ТМ. 44б].

Мөхәммәдъяр поэмаларында *-айым/-айын* формасы I зат күплек санда боеру-кушу мәгънәсен белдерү өчен дә кулланыла: қыйлайым барчамыз аңа ғушмали [ТМ. 46а]; тәңре биргән ниғмәтен бергә күрәйем, кил фәқир, ақчаңа уртақ булайым [ТМ. 63б].

Теләк фигыль Мөхәммәдъяр иҗатында I зат берлектә *-айын, -әйен, -айым, -әйем* кушымчасы белән белдерелә:

Мөхәммәдъяр поэмаларында фигыльне өйрәнеп, Н. Борһанова бу кушымчаның 1) теләкне, 2) тәкъдим катыш теләкне, 3) теләк катыш үтенүне, 4) кисәтүне белдерергә мөмкинлеген мисаллар белән раслый [Бурганова, 1980, с. 82].

Борынгы чор әдипләре иҗатында I зат күплек формасы *-алум/-әлүм* аффиксы белән килә. Л. Җәләй бу форманың кулланылу үзенчәлекләре

турында да кызыклы күзәтүләр ясый. Ул бу кушымчаның «составы ол/ал (бул) ярдәмче фигыль һәм *-ум/-ым (мин)* элементларыннан тора» һәм «-алум/-алым → -алыйк, → -айык → -ыйк//-ик формаларында йөри», ди [Җәләй, 2000, б. 181].

Без дәхи андан ришайәт қылалум
Нәзым идүб рушан хиқайәт қылалум [ӨК. 46].

Тәңре ады берлә сүзә керәлүм,
Шәреғ гөлзарында гөлләр деләрүм,
Мөбтәдәгләр мәзхәбене куйалум
Мостафаның сөннәтенә ойалалум [ӨК. 46].

Автор бу очракларда, турыдан-туры укучысына эндәшеп, үзенең теләкләрен укучысына аңлата. Мисаллардан күренгәнчә, шагыйрь үз исеменнән күплек санда сөйли. Мөхәммәдъяр поэмаларында I зат күплектә, *-алым/-әлем* формасыннан тыш, *-алың/-әлең, -алын/-әлен* кушымчалары да файдаланыла:

Йахшы қылдың биреб, алыб сән балық
Моны йийеб тәңрегә қоллық қылалық [ТМ. 63].

Мөхәммәдъярда *-алым/-әлем* шулай ук берлектә булырга мөмкин:

Бу йетинең берсе әйде шаһқа уш
Әйтәлем сезгә бу дәм бер пәнд хуш [ТМ. 44].

*-алым/-әлем* кушымчалары Максуди иҗатында да I зат берлек санны белдереп килә:

Бу сүзе ошбу арада қуйалым
Нә ғәләмәт күрде җәдде дийәлем [Максуди].

Бу форма Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында да шул мәгънәдә чагылыш таба һәм аны Ф. Хисамова «аерым очракларда I зат берлектә кулланылуы югары стиль чагылышы булса кирәк» дип билгели [Хисамова, 1977, б. 136].

I зат күплек формасы *-алым/-алың/-алық* кушымчаларын ала. Алар бер мәгънә – нindидер бер эшне эшләүгә чакыруны, өндәүне белдерәләр: йахшы қылдың биреп, алып сән балық, моны йийеп, тәңригә қоллық қылалық [ТМ. 63а]; мондин үзгә безгә йахшы йуқ һаман, анлар эшен бетерәлең бу заман [ТМ. 65б]. Түбәндәге мисал *-алың* формасының I зат берлек санда өндәү мәгънәсен белдерү өчен кулланылганын күрсәтә: бер хиқайәт килде йадға дилпәзир, килтерәлең хезмәтеңгә уш нәзыйр [ТМ. 52а].

II зат берлек санның ике формасы бар: фигыль тамыры һәм *-гыл* формасы. Мөхәммәдъяр поэмаларында икесе дә киң кулланылган һәм алар арасында бернинди семантик аермалык юк. Бу формалар түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

а) боеру, кушу: нәчә үртәрсәң дидем сән, и күңел,қуй мәне үз хәлемә, мәндин түнкел [ТМ. 44а];

ә) киңәш бирү төсмере белән әйтелгән боеру (бигрәк тә юклык формасында ачык күренә): ғақыйл улсаң, иргә касд итмә, зинһар [ТМ. 61б];

б) кисәтү, янау төсмере белән әйтелгән боеру: йырақ торып, хәдден чақлағыл, тирен суйғамән, әдәб сақлағыл [ТМ. 48а]; йуқ ирсә, йырақ торып, бул сәламәт [ТМ. 46б];

в) үтенү төсмере белән әйтелгән боеру: шаһ қызыйға диде рәғийәт қызы, тәңре өчен мәңа раст айғыл сүзи [ТМ. 53а];

г) үз-үзеңә боеру, өндәү: Йармөхәммәт, сүзне туғры сүзләгел, игре тартып, уқны туғры кезләгел [ТМ. 62а];

д) үтенеп мөрәҗәгать итү: китәргел қайғыны, булсын күңел шад, бала wә рәнҗү- михнәтдин қыйл азад [ТМ. 50а].

Мөхәммәдъяр поэмаларында II зат күплек сан *-ың/-ң, -ыңыз* кушымчаларын ала. Моннан тыш, *-ыңлар* формасына берничә очрак бар: салыңлар [ТМ. 50б]; кереңләр [ТМ. 50б]. Әлеге формалар түбәндәге мәгънәләрне бирү өчен кулланылган:

а) боеру, кушу: әйде: моны ил ташындин гиздерең, йөзенә қара сөртөп үлтерең [ТМ. 57а]; йәнә фәрман булғай әһле беһештә, кереңләр тип сезләр беһештә [ТМ. 50б];

ә) киңәш бирү төсмере белән әйтелгән боеру: мәнмәнлек қылып, мәнмәнлек сатмаңыз, онға кибәк, серкәгә су қатмаңыз [ТМ. 59б]; әйде: и ахмақлар сез орошмаң, бер данке өчен ата- анаң сүгешмәң [ТМ. 62б];

б) үтенү: әйде анларға: хода хақы өчен бәйан әйләң, кемләрсез, тәңре өчен [ТМ. 52а].

III зат берлек сан *-сун/-сүн* кушымчасы ярдәмендә ясала. *-сын* варианты сирәк очрый. Әлеге форма Мөхәммәдъяр иҗатында түбәндәге мәгънәләрне бирү өчен кулланылган:

а) III затка юнәлдерелгән боеру: сән айтғыл ул шомға, хәддени белсен [ТМ. 48б]; әйтте: мәндин улғыл имди азад, сеңа зәхмәт тикмермәсүнадәм зат [ТМ. 49б].

ә) кисәтү: нәфсең атыны сылама сән, и йар, ул йықмасын мендәрдә, зинһар [ТМ. 58б];

б) киңәш: алғыл нанны, һичкем ирсә белмәсен, қуйныңа сал, зинһар, атам кәрмәсен [ТМ. 61а];

в) нәрсәнедер эшләргә теләк булу: қыйлдым ушбу Төхфәнамәне, мәндин соңрағларға булсын йадкәр [ТМ. 64б];

г) тыю (булдырмый калу, саклану]: берничә көндин соң шаһ әйде үзе: йалғызлықдин ирекмәсен бу қызый [ТМ. 53а];

д) яхшы яки начар теләк: йәшең озын булсын һәмин [ТМ. 66б].

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» әсәрендә бу төр фигыльләрнең саны күп түгел. Мисаллар: بار بولسون – бар булсын; ياربولسون – яр булсын [ЗвК. 62b]. Юклык формасы: بو بيردين – булмасын [ЗвК. 62а].

Казан ханлыгы чоры ярлыкларында III зат берлек сан формасы очрый. Ибраһим хан ярлыгында *-сун/-сүн* кушымчасы ялганса, Сәхибгәрәй хан ярлыгында *-сын/-сен* варианты ярдәмендә ясала: қылмасынлар, мөсәмма салмасынлар, теләмәсенләр, илче-қунақ қундырмасынлар, төтен саны дип алмасынлар, ноксан-зарар тигермәсенләр, доға wә алқыш қылсынлар, зәхмәт-йынчуғ тигермәсенләр [Сәхибгәрәй хан ярлыгы], урманларина йүрүмәсүнләр, анбар алмасунлар, қунақ қундырмасунлар, тикермәсүнләр [Ибраһим хан ярлыгы].

*Шарт фигыль.* Шарт наклонениесе икенче бер эшнең үтәлүе өчен кирәкле шарт мәгънәсен белдерә һәм гомуми төрки формасы *-са/-сә* аффикслары ярдәмендә ясала. Мөхәммәдъяр поэмаларында бу наклонениенең бер гади һәм өч катлаулы формасы бирелгән. Гади форма хәзерге татар әдәби телендәге кебек үк, *-са/-сә* кушымчасы ярдәмендә ясала. Истәлекләрдә I зат күплек формасы бер тапкыр да кулланылмаган.

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | алсам | алсақ |
| II зат | алсаң | алсаңыз |
| III зат | алса | алсалар |

Поэмаларда *-са* кушымчасы шарт мәгънәсен һәм шарт модальлегенең түбәндәге төсмерләрен белдерүдә дә кулланыла:

1) икенче бер эшне эшләүченең (яки эшләмәүченең) шарты булып торучы хәрәкәтне белдерә. Бу мәгънә контекстта *әгәр/гәр* теркәгече булганда ачык күренә: хөрмәт артар, кеше сақласа намус [ТМ. 48б]; ушбу ‘Төхфә’ тарихын гәр сорсалар, туқуз йүз қырық алтыдыр белсәйләр [ТМ. 64б];

2) шартлы-үткәреп җибәрүче мәгънәсен белдерә: кеше сәндин күңел өзсә, сән өзмәгел [ТМ. 60а]. Хәзерге татар әдәби телендә бу мәгънә *-са* кушымчасы һәм *да/дә/та/тә* кисәкчәсе белән бергә бирелә;

3) шарт-вакыт мәгънәсен белдерә: дошманым зәғиф тийү күңлендә тотма, форсат эстәр, һәр заман wақыт сақлар, һәм нәүбәт улса, без тик қақлар [ТМ. 48б];

4) шарт-максат мөнәсәбәтен белдерә: әйде: уғлан йахшы булсын тисеңез, дарусы Заһиддадыр чун сурасаңыз [ТМ. 57б];

5) шарт-сәбәп мөнәсәбәтен белдерә. Бу очракта контекстта ‘кайда?’ сорау алмашлыгы була: белмәгәй сүзнең мазасын һәр би хәбәр, қайда белгәй, ғақлы булса мохтәсар [ТМ. 64б]; бер кешенең ике булса дошман, қайда тынғай ул кешенең бер җаны [ТМ. 54а];

6) сәбәп-эзләү мөнәсәбәтен белдерә: буйлә булыр, кем насихәт алмаса,олуғлар сүзен қолаққк салмаса [ТМ. 47б]; кем йаманлық қыйлса, ул тапға җәза [ТМ. 55а];

7) теләкне белдерә: ул қыз әйде: и серләрне белгән падишаһ, мәне бүре қыйлсаң ни булғай, илаһ [ТМ. 53б];

8) *кәрәк* сүзе белән *-са* кушымчасы бергә килеп, кирәклелек, киңәш, кисәтүне белдерә: әйде: и Чынбел дана, сөхәндан, кәрәк сән үчүмезне алсаң андан [ТМ. 48б].

Мөхәммәдъяр поэмаларында *-са* + *иде* (аналитик формасы] сирәк очрый. Ул үткәндә реаль булмаган шартны белдерә: анда мәнем сүземне алсаң иде, күрмәгәйдең бу бәла, дип сүзләде [ТМ. 57а].

Өмми Камал әсәрләрендә, әдәби нормадан аермалы буларак, бу төркемчәнең аналитик формасы да кулланылган, аның күрсәткече булып *исә* ярдәмлеге тора:

ارمغاننك وار ايسه اولوم ديله
Әрмәғәнының wар исә үлүм дилә [ӨК.47]

هر نهدين كم قورقار ايسه قورتوله
Һәр нәдин кем қурқар исә қортула [ӨК.46]

ديلر ايسنك آسان اوله سنكا قامو ديشوار
Диләр исәң асан улә сәңә қаму дишwар [ӨК.3]

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлегендә шарт наклонениесе дә автор тарафыннан еш кулланыла: آتسا ‘атса’[ЗвК. 60b], اولسا ‘улса’ [ЗвК. 60b] h.б.

## 3.6.2. Затланышсыз фигыль формалары

*Сыйфат фигыльләр. -р/-ар/-ыр/-ур/-йур* формалы сыйфат фигыль. *-йур* варианты тамыры сузыкка беткән сүзләргә ялгана. Мөхәммәдъяр поэмаларында түбәндәге формалары гына күрсәтелгән: тыңлайур [ТМ. 49а], аңлайур [ТМ. 49а], йоқлайурда [ТМ. 65б].

*-р* формалы сыйфат фигыль түбәндәге функцияләрдә килә:

а) аергыч: шаһдин артық сәвәр куйғашы мән [ТМ. 46б]; йахшылық қәдерене белмәс ахмақ [ТМ. 66б].

ә) тәмамлык: аңа ул эш килерен белмеш идем [ТМ. 66б].

б) хәл функциясендә килгән очракта *-р* формалы сыйфат фигыльнең урын-вакыт килеше кулланыла: ултырырда бу икәгү нәғәһан, килде саил кем ишеккә ул заман [ТМ. 63б].

*-р + да* (ягъни *-р* формалы сыйфат фигыльнең урын-вакыт килеше) формасы татар теле диалектларында да сакланып калган. Мәсәлән, нократ сөйләшендә: без белердә урман иде бу йирләр.

*-ған/-қан* формалы сыйфат фигыль. Мөхәммәдъяр иҗатында *-ған* формасы аергыч буларак кулланылган: ул қапқан җәрәхәт [ТМ. 48б]; йылан суққан им [ТМ. 57б].

*-ған* кушымчалы сыйфат фигыльнең исемләшкән формасы тартым һәм килеш кушымчалары ала һәм җөмләдә башка кисәкләр ролендә дә килә ала:

а) ия: аны күргән ғәқлидин шәйдә булыр [ТМ. 52б]; мәне сәwгән бақый қалыр [ТМ. 54а];

ә) тәмамлык: эwендә булғанын килтер [ТМ. 60б]; биргәнингә сән кәнәғәт қыйлмасаң [ТМ. 55а]; ир атанғанға мөрәwwәт һәм кәрәк [ТМ. 55а];

б) хәл: кем йығылғанға қулын тот бер моңлының [ТМ. 403]; тапмағандин орышырлар икесе. Рузи кылғай ғадел кылғанға үкүш [НС. 43].

Шагыйрь иҗатында *-ғаны + йуқ* формасының бердәнбер очрагы бирелгән: кәрәкмәс эш һәргиз қыйлғаны йуқ ирле [ТМ. 61б].

*-ған* формасы сыйфат фигыль функциясендә Ибраһим хан ярлыгында һәм Сәхибгәрәй хан ярлыгында да күзәтелә: Бу азад йибәргән кем ирсәләрнең аты [Ибраһим хан ярлыгы], Ийәсе суйурғаб биргән бу икенең тамға урманын [Ибраһим хан ярлыгы], сәфәрләрендә wә Хәзәрларында, ултырғанларында wә торғанларында, кешеләренә wә қараларына, йөкләренә wә чарwаларына... [Сәхибгәрәй хан ярлыгы].

Сыйфат фигыльнең *-ған/-гән* кушымчасының угыз варианты *-ан/-ән,* Өмми Камал әсәрләрендә ике сузык аваздан соң килгәндә *-й* өстәлә. Күп очракта сыйфат фигыльнең бу формасы исемләшеп килгән.

كم زنادن توبه قيلسه قورتوله
ليك غيبت سويليان بورچلو قاله
Кем зинадан тәүбә қылса қортулә
Лик ғайбәт сөйләйән бурычлу қалыр [ӨК. 48].

جمله سين سومك كراك دور جانيله
سوميان كم دور روافض صانيله
Җөмләсен сүмәк кәрәкдүр җанилә
Сүмәйән кемдүр рәуафид санилә [ӨК. 51].

Коръән тәфсиреннән мисаллар да бу кушымчаның угыз варианты кулланылганлыгын исбатлыйлар: Қоръән индүрән җабраил хаққы wә Қоръән уқуйан мөэминләр хаққы [Кт. 45].

*-мыш* формалы сыйфат фигыль Мөхәммәдъяр иҗатында киң кулланылган. Ул түбәндәге функцияләрдә килә: а) аергыч: кәчмеше хален [ТМ. 57б]; қара булмыш йөзем [ТМ. 59а]; кисмеш әле [ТМ. 62а]; ә) тәмамлык: җаны қотолмышына булып шадман [ТМ. 56]; ник башындин кәчмешен әйде барын [ТМ. 56]; бик һәм қылмышыдин уфтанды [ТМ. 57б]; б) хәл: бер көн бик шадман булмышында [ТМ. 45а]. Бу форма Өмми Камал иҗатында да очрый: Һәм һидайәт wир без азмыш қолыңа [ӨК. 38]; Бизәнмәмеш хурлары торур [ӨК. 56].

*-дық/-дек* формалы сыйфат фигыль. Мөхәммәдъяр әсәрләрендә бу форма очрамый. Өмми Камал иҗатында аның исемләшкән варианты еш күзәтелә: اول حبيبه قيلدوغنك اعزازه اوچون – Ул хәбибә қылдуғың иғзәзә өчен [ӨК. 39]; бересе қақыдуғын йотмақ кәрәк [ӨК. 49], қани кидүкләре ул дүрлү хыйлғәт [ӨК. 79] һ.б. Бу форма Коръән тәфсире өчен дә ят түгел: Һаман болар турдуқлары йирдә бер уғурдан кәчдүләр [Кт. 102].

*-учы/-үче* формалы сыйфат фигыль. Чапыңыз тәүбә кылучы берлә нәфсең буйнуны [ӨК. 49].

*-ғучы/-гүче* формалы сыйфат фигыль. Бу форманың юклыгы Мөхәммәдъяр әсәрләрендә бирелмәгән. *-учы* формалы сыйфат фигыль кебек үк, *-ғучы* зат тарафыннан үтәлеп торуны, аның һөнәре булуны белдерә. Поэмаларда бу форма түбәндәге функцияләрдә килә: а) аергыч: и теләкләр биргүче хақ [ТМ. 50а]; ә) тәмамлык: йаманлық қыйлғучыға қылма йаман [ТМ. 60а]; б) ия: йарлықағучы улдыр [ТМ. 62а];

үчемезне алғучы җәббардыр [ТМ. 52а]; в) хәбәр: һәйбәт илә әйде: без биткүчемез, тәңре ни сурса, аны әйткүчемез [ТМ. 52а]; һәр ни қыйлсаң, биткүчеләрдер анық [ТМ. 51б].

Мөхәммәдъяр поэмаларында *-ғусы/-қусы* формалы сыйфат фигыль урын алган. Ул киләчәктә үтәлергә тиеш булган эш-хәрәкәтне белдерә: сәңа бу көн дошманлық иткүседер, ғафилыкда башыңа йиткүчедер [ТМ. 66а]. Бу формага татар теле һәм аның диалектларында (нигездә, урта диалектта] *-асы/-әсе* формасы туры килә. Бу форма Өмми Камал иҗатында [ӨК. 37], Коръән тәфсирендә актив: Дөнйа сүгүси сүчиси мәсти [Кт. 87].

*-асы/-әсе* формалы сыйфат фигыль Мөхәммәдъяр иҗатында актив түгел, бары бер куплетта гына очрый: аһ, киләсе худ килмәс димә, кем буласы кем булыр, булмас димә [ТМ. 51б]. Өмми Камал шигырьләрендә дә сирәк очрый: Бу қуйуб кидәсе йорды йапарсән [ӨК.70].

*-мачы* формалы сыйфат фигыль «Төхфәи мәрдан»дә бер тапкыр гына кулланылган: булмачы сүзгә қолақ тотмақ кәрәкмәс [ТМ. 60а]. Мөхәммәдъярның истәлекләрендә ‘булмачы сүз’ дигән гыйбарә, мөгаен, алдагы чорлардан ук килә. Истәлекләрдә, мәсәлән, Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында ‘булмачы эш’ сүзе киң кулланылган.

*-ачақ/-әчәк* формалы сыйфат фигыль формасы Өмми Камал иҗатында, Коръән тәфсирендә урын ала: қийәмәтдә торачақ өммәтләр хаққычүн [Кт. 45], қурқачақ мәнзил дорур зирәкә гүр [ӨК. 47].

Нәтиҗә итеп, XV–XVI гасырлар чыганакларында үткән заман сыйфат фигыльнең *-ган, -мыш, -дык* формалары төрле ешлыкта килә: Мөхәммәдъяр поэмаларында, Ибраһим хан һәм Сәхибгәрәй хан ярлыкларында, «Зафәрнамәи вилаяте Казан» әсәрендә, Кол Шәриф текстларында сыйфат фигыль функциясендә *-ган/-гән* кушымчалары өстенлек итсә, хикәя фигыльне белдерүдә *-мыш* формасы актив. Ярлыкларда беренче төр бөтенләй очрамый, бары тик *-ган* кушымчалы сыйфат фигыль формасы гына күзәтелә. *-ган* кушымчалы сыйфат фигыль, исемләшеп, тартым, килеш, сан кушымчалары ала. Атрибутив, предикатив, субстантив функцияләрдә кулланыла торган *-р/-ыр/-ер* кушымчалы сыйфат фигыль дә бу чор язма истәлекләрендә актив, һәм ул да, еш кына, исемләшә. Әлеге кушымчаның юклык формасы *-мас/-мәс* «Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлегендә *борын* сүзе белән янәшә килеп, төп фигыльдә белдерелгән процессның тәмамлану вакытын белдерә: Әй Шәрәфи мустәғид булмақ кәрәк үлмәс борун [ЗвК. 61б] Әй, Шәрәфи, әзерләнү кирәк, үлгәнче үк. Л. Будагов, аны казан һәм

кыргыз телләренә хас дип билгели [Будагов, 1869, б. 278]. Алтын Урда чоры текстларында бу мәгънәдә аның *-масдин борун* формасы килә [Боровков, 1963, с. 111; Фазылов, 1966, с. 279].

*Хәл фигыльләр.* Хәл фигыль формалары XV–XVI гасыр язма истәлекләрендә бик күп.

*-ыб/-еб* формалы хәл фигыль Мөхәммәдъяр поэмаларында киң кулланылган һәм төрле синтаксик функцияләрдә катнаша. Вакыт мөнәсәбәтенә карап, түбәндәгеләрне белдерә:

а) икенче бер эш-хәлдән алда үтәлгән эш-хәлне: бүрене күрүб төгәл илә қачтылар [ТМ. 53б]; төрлүк йимеш килтереб, йигел тиде [ТМ. 56а].

ә) икенче бер эш-хәл белән бер вакытта үтәлгән эш-хәлне: йөрер ди үзен ғәйәт сусатыб [ТМ. 55б]; игре тартыб, уқны туғры кизләгел [ТМ. 62а].

*-б/-п* формалы хәл фигыль, икенче эш-хәлнең билгесе буларак, түбәндәгеләрне белдерә ала:

а) икенче эш-хәлнең башкарылу рәвешен, ысулын: бүре булып йиде ул қызны тәмам [ТМ. 53б]; андим килдем рәwан мән ашықып [ТМ. 57а];

ә) икенче эш-хәлнең вакытын: күреб Хушхун аны дәрхал торды [ТМ. 49б];

б) икенче эш-хәлнең сәбәбен: йебе черегән белде, һич кемсә алмады, йаман ирер тиб күзгә салмады [ТМ. 63а];

в) икенче эш-хәлнең максатын: форсат ирзәп нәчә wақыт сақладылар [ТМ. 65б]; килде қойуғ башына су бармы тиб [ТМ. 55б].

Поэмаларда карап үтелгән форма баш кисәкләр ролендә (күп очракта хәбәр ролендә) катлаулы, шул исәптән гади җөмләләрдә дә килә:

а) иярчен җөмләнең хәбәре функциясендә: доғасы хақ хәзрәтендә төш килеб, һәлақ булды атасы... [ТМ. 61б];

ә) тезмә кушма җөмләнең беренчесендә хәбәр функциясендә: хатыны игәреб ул мамықны, йеп итеб, ире сатар ирде чықарыб [ТМ. 62б]; күңел әйтер: ни қыладыр мән сәңа, тел озатыб һәр замандырсән мәңа [ТМ. 54б];

б) тиңдәш хәбәрләр сыйфатында. Бу конструкцияләр хәрәкәтнең, вакытның берсе артыннан берсе яки тиз арада алышынып торуын белдерәләр: кереб қаплан, ул қызыйны үлтереб, алтын-көмеш буйнидин тартыб алыб, бер хәмаил бирде энҗү данәлық [ТМ. 56б].

Мөхәммәдъяр иҗатында фигыльләре *-ыб/-еб* формасы белән бирелгән бәетләр (юллар] бар: Заһид асайыш қыйлу ултырыб, йимеш илә йиңитәген тултырыб [ТМ. 56б]; ултырыб сән, солтанатлық тәрк итеп, нә сәбәпдин сәне монда беркетеб [ТМ. 53б].

Шулай итеп, Мөхәммәдъяр иҗатында *-ыб/-еб* формалы хәл фигыль киң кулланылган.

Колшәриф иҗатында да бу очракка мисаллар шактый: Уғылны анадин айруб, қызны анадин тәқи / Йығлатыб бер-бер ишекдә, зари қылған дөнйадыр [КШ. 32]; Күзең ачыб бакыб тор, ғәфил йөрмә, һу дигел [КШ. 29]; Айрулуб мән баламдин, имди қайа барайын [КШ. 50].

Шәриф Хаҗитарханиның «Зафәрнамәи вилаяте Казан» әсәре телендә дә *-ыб/-еб*/-б формалы хәл фигыль бик актив кулланыла: سوقوب – суқуб, كوتروب – күтәрүб, بريب – биреб, بولوب – булуб, ا شتيب – ишетеб [ЗвК. 61а] һ.б.

Өмми Камал иҗатында *-ыб/-еб* варианты белән бер үк ешлыкта *-уб/-үб* формасы да урын ала:

هر نه يى كم كوره ياخود ايشده
آنى آنده صاقلايوب پنهان ايده
Һәр нәйе кем гүрә йәхүд эшдә
Аны анда сақлайуб нәнһан идә [ӨК. 48].

تجفه لارنك چونكه شاهه عرض اوله
سوچله رنكى عفو ايدوب رحمت قيله
Төхфәләрең чөнкә шаһә ғарз ула
Сүчләреңе ғафу идүб рәхмәт қыла [ӨК.47].

Коръән тәфсиренә карата да бу очракта шул ук фикерне кабатлап була: Ибраһим дәхи аны күрүб, намаздан фариғ улды [Кт. 65]; Сабыр идәмәйүб, кирү әл озатды [Кт. 65]; Ануң айәтләрен уқуйуб, мәғнәсен дә кәфәккур қылалар [Кт. 102]; Кәлүб Әйүбә ғәүрәте ул хәбәре дәкүрде [Кт. 110]; Ануң айәтләрен уқуйуб, мәғнәсен дә кәфәккур қылалар wә ғақлы уланлар ануңилә үгүтләнәләр [Кт. 102]; Пәс Әйүб йөз тазә мәдсин чыбуғын алуб, ануңилә беркәз әһлене урды [Кт. 110]; Болар аны күрүб, хәбәр бирүрләр [Кт. 81].

*-бан/-бән* формалы хәл фигыль хәзерге татар әдәби теленә дә, диалектларга да хас түгел. Бу форма *-у/-ү* формалы исем фигыль һәм *белән* бәйлеге бергә килүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Хәл фигыльнең угыз телләренә хас *-бан/-бән, -убан/-үбән* формаларының берничә урында очравын һәм бу чор язма истәлекләрендә актив түгеллеген искәртергә

була. Мөхәммәдъяр иҗатында, Кол Шәриф шигырьләрендә килә: Кем йәнаша тезелмеш йети тәмүғ / Тотубән мәне анда килтүрдиләр [НС. 59]; Ир сәхәрдә қубубән, тулдырмайен күздү йәши [КШ. 34], әғзәләрүң черүбән, ахирәткә хақ булур [КШ. 50]; Таң йарубән сөбх wә сәхәр орды дәм [ТМ. 52б].

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» әсәрендә бер тапкыр, *-ыб/-еб* аффикслары кебек үк мәгънә белдереп, *-убән* кушымчасы очрый: قویوبن – қуйубән [ЗвК. 62а].

> یوز دوتوبن اللهنکا
> یالواره سن یالواره سن
> Йөз дотубән Аллаһыңа
> Йалwара сән йалwара сән [ӨК.81].
>
> یر التونده یاتوبن استومزده
> Йер алтунда йатубән өстүмездә [ӨК.75].

*-а/-ә* формалы хәл фигыль. Мөхәммәдъяр иҗатында бу форма чикләнгән күләмдә кулланылган. Башлыча, катлаулы фигыль формаларында очрый: бақа қалды [ТМ. 47б]; күрә белмәй [ТМ. 48а]; сата алмайын [ТМ. 63а]. Ул, җөмләдә хәл буларак, төп хәрәкәт белән бер үк вакытта булган һәм аның сыйфатына, тәмамлану ысулына күрсәткән хәрәкәтне белдерә: берәгү балық сата ултырыр йулында [ТМ. 63а]. «Төхфәи мәрдан» поэмасында бу форма яңадан кабатланмаган.

*-у/-йу* формалы хәл фигыль. Элекке чор истәлекләрендә *-а/-у/-йу* формалы хәл фигыль бер форманың фонетик вариантлары буларак карала [Шербак, 1961, с. 158; Кондратьев, 1970, с. 41–43]. Ә Мөхәммәдъяр иҗатында *-а* һәм *-у/-йу* формалары арасында функциональ һәм семантик яктан беркадәр аерма бар. *-у/-йу* формалы хәл фигыль, *-а* формалы хәл фигыльгә караганда, ешрак һәм төрле мәгънәләрдә очрый. Хәл ролендә килеп, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

а) икенче эш-хәлнең рәвешен, ысулын: Заһид асайыш қылу ултырыб [ТМ. 56а]; күксе уты йылнайу дәрхал торды [ТМ. 47б]; сүзләйү сүз қаплан эшигә йитте [ТМ. 57б];

ә) икенче эш-хәлне башкаруның максатын: йахшы, йаман кемләр имеш аңлайу, йөрер иде үзе эwләр тыңлайу [ТМ. 52а]; теләнчеләйү бер эwгә килде [ТМ. 61б].

Хәл фигыльнең шулай ук *-у/-ү/-йу* формасы Колшәриф иҗатында да күзәтелә: Сән сағынма дөнйада мән бақый қалғаймән тийү [КШ. 32]; Раббе тийү, аңа бакса, кәлүр ләббәйкә йөз-мең йандин [КШ. 34].

*-у/-йу* формалы хәл фигыль хәзерге әдәби телдә искергән форма санала. Күрәсең, ул халык сөйләменә дә хас булмаган. Диалектларда (алда күрсәтелгән мәгънәләрдә) *-а/-ә* формалы хәл фигыль актив кулланыла (мәсәлән, мишәр диалектында, казан арты сөйләшләрендә): җөгөрә бара; печән чаба китте [ТТДС, 1993, б. 444].

*-май/-майын* формалы хәл фигыль. Бу форма – алда карап үтелгән хәл фигыль формаларының юклыгы. Бу чор истәлекләрендә күбрәк *-майын* формасы очрый. Мөхәммәдъяр поэмаларында *-май/-майын* формалы хәл фигыль түбәндәге очракларда кулланылган:

а) икенче эш-хәлнең башкарылу рәвешен, ысулын: кәчәләр сүзләмәйен сүз гөлене кистеләр, сүзләгәнне күрә белмәй тән тишеп, қан эчтеләр [ТМ. 44б]; ни йиргә бармақны белмәйен булды әwарә [ТМ. 61а];

ә) икенче эш-хәлнең кире шартын: соңра бер көн хәстә тикде җанына, ғалиб улын, бақмайын дәрманына [ТМ. 59а];

б) икенче эш-хәлнең максатын: сүзен үзгә итмәйен бирдем сәңа [ТМ. 66а].

*-май/-майын* формалы хәл фигыль аергыч ролендә дә килә: бел: соңыны бақмайын эш иткәннәр, наданлықдин үз башына йиткәннәр [ТМ. 60б].

*-майынча* формалы хәл фигыль Өмми Камал иҗатында урын ала:

خدانںك فضلى يولداش اولماينچه
Ходаның фазлы йулдаш улмайынча [ӨК. 73].

ياردام اولمايونچه اول سلطان دان
Йәрдәм улмайунча ул солтандан [ӨК. 24].

*-мадин* формалы хәл фигыль – хәл фигыльнең борынгы формасы. Ул «Төхфәи мәрдан» поэмасында очрый һәм бер генә тапкыр ияртчен вакыт җөмләнең хәбәре функциясендә кулланылган: кем доғасын қыйлмадин Һәнүз тәмам килде нида... [ТМ. 62а].

Ул шулай ук Өмми Камал шигырьләрендә дә урын ала һәм шактый актив: Йөз қырағына чықа күр батмадин [ӨК. 27]; Сормадин беләң, бақмадин күрән / Сонмадин дотан, атмадин оран / Дыңламадин аңлайан, ишедән [ӨК. 37б]; Кәрә күр ул қапуйа йапылмадин [ӨК. 50].

*-мадин* формалы хәл фигыль борынгы төрки истәлекләрдән «Котадгу белек» (XII г.), «Тәфсир» (XIII г.), «Кыйссәсел-әнбия» (XIV г.) һ.б.да кулланылган [Щербак, 1961, с. 160–161; Наджип, 1975, с. 171]. Мөхәммәдъяр әсәрләренә бу форманың борынгы һәм урта гасыр төрки

истәлекләре йогынтысы нәтиҗәсендә килеп керүенә шик юк. *-мадин* формасы татар сөйләшләренең берсендә дә билгеле түгел, ә хәзерге татар әдәби телендә аңа *-мый/-мыйча* формалары туры килә.

*-ганча/-гәнчә* формалы хәл фигыль Мөхәммәдъяр поэмаларында түбәндәге очракларны белдергәндә кулланылган:

а) башка фигыльнең хәрәкәте дәвам итеп туктаган вакытка күрсәтүче чикне: терек улғанча сәнең қәдрен белеб [ТМ. 56б]; мән килгәнчә лотфы әйлән туқтағыл [ТМ. 56б];

ә) икенче эш-хәлнең башкарылу дәрәҗәсен, чамасын белдерә: кем қулындин килгәнчә қыл йахшылық [ТМ. 56б]; Ул доғаны мән уқудым ирсә уш / Күз йомуб ачғунчә килдем эwгә хуш [ТМ. 52]; Йомуб ачғунчә күзүңни сән рәwан / Теләгән йиреңә тиггел бу заман [ТМ. 52]; Көз йумуб ачғынча (10б) [Наджип, 1989, с. 165]. Әлеге мисалларда бу форма тотрыклы сүзтезмә, ягъни фразеологик берәмлек эчендә килә.

Татар теле диалектларында бу формага охшаш *-ганча/-ганчы/ -гынча/-гынчы/-гинча* формалары кулланыла.

Мөхәммәдъяр иҗатында *-гач/-гәч* формалы хәл фигыльнең бердәнбер очрагы күрсәтелгән: таң йаруғач, иргә бирде сатмаға [ТМ. 658]. Сәхибгәрәй хан ярлыгында да бер урында бу очракка мисал бар: Бәса болайу тийү торғач, йарлығ тыңламай көч-басыч, зәхмәт-йынчуғ тигергән кешеләрнең үзләренә ни йахшысы булғай диб, ал нишанлығ йарлығ бирелде [Сәхибгәрәй хан ярлыгы]. Бу форманың сирәк кулланылуы, күрәсең, аның башка фигыль формалары белән алышынуында. *-ды + исә //-дисә* формасы – аның актив синонимы.

*-галы/-гәле* формалы хәл фигыль. Текстта түбәндәге мисаллар китерелгән: атасы йуқында бер саил килде қулғалы, тапмады қыз аңа нәрсә биргәле [ТМ. 60б]; җәмғ иткәле йари бирде қардеғар [ТМ. 64б]. Мисаллардан күренгәнчә, *-галы* формалы хәл фигыль истәлектә башка фигыль хәрәкәтенең максатын белдерә. Шул ук мәгънәдә ул татар диалектларында да сакланып калган [Тумашева, 1977, б. 84, 200, 232–233; Йосыпов, 1988, б. 87].

*Исем фигыльләр.* Мөхәммәдъяр поэмаларында исем фигыльнең *-мақ/-мәк, -ма /-мә, -у/-ү* һәм *-ыш/-еш* формалары урын ала.

Мөхәммәдъяр поэмаларында *-мақ/-мәқ* формалы исем фигыль киң кулланыла һәм төрле синтаксик функцияләр башкара: а) ия буларак: бу тиңсезгә тиң алдырмақ тикәрмү? [ТМ. 49а]; ә) тәмамлык функциясендә: теләң бәд нәсфәдин азад булмақ бер үзгәгә килсә

йахшы – шад булмак̡ [ТМ. 60а]; ни йиргә бармак̡ын белмәйен булды аwарә [ТМ. 61]; б) хәл функциясендә: сүзләмәкдә сән йөземне ак̡ к̡ыл [ТМ. 44б]; әйде: үзгәгә хаҗәт ирмәс бармак̡ға [ТМ. 44б]; в) катлаулы хәл буларак: йул кисеп, мал алмак̡ иде эшләре [ТМ. 64б].

Бу форманың юклыгы поэмаларда урын алмаган.

*-мак̡* формалы исем фигыль, *кәрәк* ‘кирәк’ сүзе белән килеп, кирәклелек мәгънәсен белдерә: ушбу эшнеӊ чарәсен к̡ыйлмак̡ кәрәк, хәйлә билә үчүмүзне алма кәрәк [ТМ. 732].

*-мак̡* формасы, бул-/ул- фигыльләре белән килеп, нәрсәнедер эшләргә теләк барлыгын белдерә: килмәк улды барча бер кәчә йығылмыш [ТМ. 732].

*-мак/-мәк* формасы Өмми Камал иҗатында да күзәтелә:

آز يمك آز اويومق آز سويلامك
Аз йимәк аз ойумак̡ аз сөйләмәк [ӨК.50].

يعنى قرآن اوقومقدور صبح شام
Йәғни К̡оръән ук̡умак̡дур сабах шам [ӨК.48].

هم صراطه ارمغان دوزمك كراك
Һәм сиратә армаған дүзмәк кәрәк [ӨК.47].

كم كيچه آندان كنكازين تيزراك
Кем кичә андан киӊәзин тизрәк [ӨК.47].

بها ديدار يچون اولمك بهادور
Бәһа дидәр ичөн үлмәк бәһадур [ӨК.70].

*-ма/-мә* формалы исем фигыль. Мөхәммәдъяр иҗатында бу форма бер генә очракта – хәрәкәтнеӊ максаты мәгънәсендә кулланылган: к̡ачан кем сүзләмә ағзым ачармән [ТМ. 161]. Ә инфинитив мәгънәсендә *-ма/-мә* формасы урта диалектның күп сөйләшләрендә сакланып калган. Татар телендә бу формадан барлыкка килгән *-малы* һәм *-мага* формалы инфинитив та бар.

Шулай итеп, татар теленең диалектлары күрсәткәнчә, *-ма* формалы исем фигыль халык телендә дә кулланылган, шуӊа күрә ул Мөхәммәдъярның телендә дә чагылыш тапкан.

*-у/-ү* формалы исем фигыль чикләнгән күләмдә генә кулланылган. Анда түбәндәге очракны күрергә мөмкин: йарлык̡ау телә [ТМ. 58а]; гафу үтен, үтенүем бар: сүкмә мәне [ТМ. 62б]; баруымда нағаһ к̡апланы күреп... [ТМ. 56а].

Истәлектә *-ыш/-еш* формалы исем фигыль кулланунының бердәнбер очрагы күрсәтелгән: туғры йулға биргел хуш йөрөш [ТМ. 58б].

*Инфинитив.* Мөхәммәдъяр поэмаларында инфинитивның ике формасы күрсәтелгән: *-маға/-мәгә, -рға/-ргә.* Аларда *-маға/-мәгә* формасы киң кулланылган һәм беренче чиратта, хәл формасында килгән: бу көн чықмыш ирде йеп сатмаға, көндәге тик тәғам алып қайтмаға [ТМ. 645]; теләр ирди бу қыз хален сурмаға [ТМ. 339].

*-маға* формасының башка синтаксик функцияләрдә килә алуы да күрсәтелгән: а) аергыч ролендә: кермәгә йир тапмады ул бичарә [ТМ. :602]; ә) ия ролендә: аңа тикмәс кем гөстахлық қыйлмаға, олуғлар рәштәсигә қатылмаға [ТМ. 57].

Шунысы игътибарга лаек: *-маға* һәм *-маққа* (*-мақ* формасының юнәлеш килеше] формалары бер мәгънәне белдерсәләр дә, истәлектә ике төрле мәгънә белдерүче кисәк буларак бирелгәннәр. Мәсәлән: сәдәқә бирмәккә [ТМ. 630], хәер кылмақға [ТМ. 653]. *-маға* формасы татар теленең диалектларында да сакланып калган. Ул – урта диалектка хас форма.

Өмми Камал әсәрләрендә инфинитив *-маға/-мәгә* формалары ярдәмендә ясалган:

صونك نفس ده كم كلور جان آلماغه
روحنكى جسمنكدان آسان آلماعه
Суң нәфсдә кем килүр җан алмаға
Рухыңы җисмеңдан асан алмаға [ӨК. 47].

آخرت ایشلرينه اولاشماغه
Ахирәт ишләринә улашмаға [ӨК. 81].

*-мақ/-мәк* формасы да инфинитив функциясендә килә. Ул Өмми Камал иҗатында да күзәтелә:

كورمك ديلرسنك آنى
Күрмәк диләрсең аны [ӨК.84].

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» әсәрендә дә инфинитивның *-мақ* аффиксы очрый: باغلماق غزاة اى شريفى مستعد بولماق كراك (ат бағламак – ат бәйләргә] [ЗвК. 60b].

Хәзерге татар телендә инфинитивның продуктив формасы булган *-рға/-ргә* кушымчасының Мөхәммәдъяр поэмаларында кулланылышына бары өч мисал гына очрады: күрергә хөсне шәһрендә ул шаһ иде [ТМ. 83]; биккә әйтергә ашықты [ТМ. 56б]; әмер қыйлды

үлтерергә [ТМ. 65б]. Инфинитивның бу формасы «Зафәрнамәи вилаяте Казан» истәлеге телендә аз санда кулланылган: بسارغه بر چوال یر:آیاق تابولماس ایردی (басарга) [ЗвК. 64b]. Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, бу истәлек барлыкка килгәнче үк, *-рга* формасы, мөстәкыйль морфологик кисәк буларак, инде расланган булган.

XV–XVI гасыр язма истәлекләренең морфологик үзенчәлекләрен тасвирлап, гомумән, бу чор әдәби телендә язма традицияләрнең саклануын әйтә алабыз. Шул ук вакытта Алтын Урда чоры белән чагыштырганда, Идел буе татар теленә хас формаларның текстларда ишәя барганы күренә. Казан ханлыгы чоры иске татар теле традицион борынгы уйгыр һәм күп булмаган угыз элементлары белән баетылган кыпчак, ягъни халыкчан формаларның кулланылышы белән характерлана.

## 4. XVII–XVIII ГАСЫРЛАРДА ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ӘДӘБИ ТЕЛЕНЕҢ МОРФОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Язма истәлекләр, тарихи фонетика, тарихи синтаксис, тарихи лексикология белән чагыштырганда, тарихи морфология өчен тулырак мәгълүмат бирәләр, дип билгелиләр тел тарихы галимнәре [Букатевич..., 1974, С. 11]. XVII–XVIII гасырлардагы татар әдәби телен өйрәнү өчен чыганаклар аннан алдагы чордагыга караганда шактый күп икәнлеген әйтергә кирәк. XVII йөз поэзиясенең эчтәлеген, телен шул чорның иҗтимагый, сәяси, мәдәни шартларының нәтиҗәсе – үзенчәлекле агым буларак яшәгән суфичылык вәкиле Мәүла Колый [МК] иҗаты тәшкил итә. Тикшеренү өчен хикмәтләрнең Зәй-Каратай нөсхәсе алынды. XVIII гасыр поэзиясе соңгы елларда күп кенә исемнәр белән баеды. Аларның иҗаты «XVIII гасыр әдәбияты. Поэзия» (2006) хезмәтендә тупланган. Габди, Габдрахман бине Туймөхәммәд Тайсугани, Габдессәлам [Гс], Исмәгыйль, Хәлилулла, Габделгафур бине Габделмәннан, Локман, Хәмид Йосыф углы, Габделмәннан Мөслимов [ГМ], Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари [УИ] һ.б. шагыйрьләр иҗаты тел үзенчәлекләре бу чор язма әдәби телен күзалларга, аларны XVII–XVIII гасырлардагы рәсми эш кәгазьләре үрнәкләре белән чагыштыру функциональ вариантлылыкны ачыкларга мөмкинлек бирә.

### 4.1. Исем

Тикшерелә торган поэмаларда исем сүз төркеменә хас килеш, тартым, сан, хәбәрлек грамматик категорияләре теркәлгән.

**Сан категориясе.** Берлек сандагы исем предметларның берлеген, ягъни бер данәдә булуын белдерә [Хисамова, 2006, б. 99]. Берлек

сан нуль формада (Ø) килә: Мәүла Колый әсәрләре телендә күплек мәгънәсен белдерүдә татар теленә хас булган ике ысул кулланыла: морфологик һәм лексик-синтаксик. Күплек санының морфологик ысулында сүзнең нигезенә *-лар/-ләр* аффикслары ялгана: җанларымыз [МК. 2], агызларә [МК. 2], удларны [МК. 2], дустлар [МК. 2], тамырларға [МК. 3б], йулларыны [МК. 5б], доғалары [МК. 5б], қырлара wap [МК. 63а] һ.б.

Күплекнең лексик-синтаксик ысулында исемнәрнең аергычлары функциясендә микъдар саннары яки күплек мәгънәсен белдерә торган аерым сүзләр кулланыла: күб җанлар [МК.], утыз өч мең йаранлары [МК. 9б], дүрт чәһарйар [МК. 9б], күб адәм [МК. 10], барча җан [МК. 15], барча хәлләр [МК. 23б], мең зарлансам [МК. 24], үкүш күрдек [Габди. 25], чуқ хәмде сәна [Гс. 51], күб сағыш [Гс. 47]; ходa сақлар сәне барча йаwыздин [УИ. 139]. Бу очракка М. Колыйда түбәндәге юллар ачык мисал булып тора: Баш милкендә Хақ йаратди ике қолақ / Хақның эшен ишетеб мәндәйлә йарақ / Изи әмрен қолақ иштүб теләк қылсын / қолақ бирде, иштеб ғәмәл қылмақ өчен / Ике қулны бирде Алла қуәт илә / Тәғәт қылыб, қул күтәреб теләк телә / ... Өч йөз алтмыш тамыр андин тулуқдыр қан / Тәндә йөрер тамырлардин йатмайын җан /.... Сәҗдә өчүн бирде Алла ике тези, Сәҗдә йирин күрмәк өчүн ике күзи / Сәҗдәгә орғыл: маңлай, ике йөзени / Ике айақ, тез Хақға сәҗдә қылмақ өчүн [МК. 16б].

Күплек саны мәгънәсе, нигездә, татар теленә хас булган грамматик чаралар һәм ысуллар (морфологик һәм лексик-синтаксик ысуллар) ярдәмендә белдерелә.

**Тартым категориясе.** Төрки телләрдә, шулай ук татар телендә дә, исем сүз төркеменең иң актив кулланылган категорияләренең берсе – тартым категориясе.

Мәүла Колый хикмәтләре һәм поэмалары телендә I затка караган тартымны белдергәндә исемнәргә берлек санда *-м, -ым/-ем, -ум/-үм,* күплек санда *-ымыз/-емез* аффикслары ялгана. Мәсәлән: Бу тәнемез бостан ирмеш ул зинданда, җанларымыз миһман ирмеш ул бостанда [МК. 2], Йарум, сән, сән, белүрсән бәнем хәлем [МК. 22б], Тәззариғ қылыб, йөзүм йиргә ордым [МК. 3]. күземез [МК. 44], сүземез [МК. 44];

II зат тартымны белдерү өчен исемнәргә *-ң/-ың/-ең* аффикслары ялгана. Мәсәлән, йәшләрең [МК. 20], күзең [МК. 4б, 12б, 20, 28б, 32б, 35б, 39, 40].

III зат тартымны белдергәндә исемнәргә *-ы/-е, -сы/-се* аффикслары кушылалар. Мәсәлән: Сабыр берлә Йосыф табды дәүләт йөзен [МК. 4], Нәтәк аны ақартайым, суы йуқдур [МК. 23б].

XVIII йөз әдипләре иҗатыннан мисаллар: Телем йуқ сүзләмәгә йарар сүз [ГМ. 59б], Ике күзем нуры син [ГМ. 59а], алдай-алдай ашың wә наның йийәр [УИ. 57], Хақ қашында уласын йаwыз атым [ГМ. 57б].

Татар телендә тартым аффиксларының кулланылуы рәт гармониясенә һәм сингармонизм законына буйсына, әмма бу чор истәлекләре телендә ул язылышта чагылыш тапмый.

**Килеш категориясе.** Килеш белән төрләнү исем сүз төркеменең иң төп грамматик үзенчәлеген тәшкил итә. Мәүла Колый хикмәтләрендә исемнәрнең килеш белән төрләнгәндә, нигездә, кыпчак төрләнеше өстенлек итә.

*Баш килеш.* Баш килештәге исемнәр формаль күрсәткечләр алмый, ягъни нуль формада кулланыла һәм күпчелек очракта баш килештәге исем эш-хәрәкәтнең субъектын белдереп, җөмләдә ия функциясендә килә: адәм йөрмәс [МК. А72а.15]; хан әйде [МК. 69а.]. Мәсәлән, Кыш көнендә үләнләр йирдә черүр, Йаз булдисә, нәбат нигъмәт үсә торур, Барча Адәм үлеб барыб, гүргә керүр, Қийамәт көн қайра терлүр, қөдрәт берлә [МК. 14б].

Баш килештәге исемнәр, эш-хәрәкәтнең туры объектын белдереп, җөмләдә тәмамлык функциясен башкарырга мөмкиннәр: Борун, ағыз бирде безгә изем әхәд [МК. 17]; Бинамазлар мал йыймақдин йуқ үзгә сүз [МК. 6б]; Мәнәт бирәм сәңа [МК. (п) 72а.]; Пер табак хәлwә мәңа шаһе бирде [ГбМ.119]; чәй пешермәккә үрәткән кемсә йуқ [УИ.59].

Мәүла Колый әсәрләрендә һәм башка истәлекләрдә баш килештәге исем бик еш эндәш сүз булып килергә мөмкин һәм аерым очракларда эндәш сүзләр текстка махсус»әй» һәм «и» кисәкчәләре ярдәмендә кертелә: хан анда диде: Әй бәдбәхет хатун [МК. 4], Мәүла Қолый, Хақға йығлаб, тәғәт қыл, сән [МК. 8б]; Мескин Ғәбди, тәғәт қылғыл тәмам ғөмрең барыңча [МК. 22]; Әй нигәрем кәчә көндез wасфыңны йад әйләрем [Гс. 43]; И җәwан, сән йәшлегеңдә тибрәнеб шәһре ислам эчинә килдең йитеб [УИ. 63].

Шулай ук «йа» гарәп кисәкчәсе, кагыйдә буларак, дин өлкәсенә караган алынма сүзләр янында һәм Аллаһка мөрәҗәгать иткәндә ешрак кулланыла: Йә Илаһым [МК. 4] [МК. А706.3]; йә Илаһым, табшырылдым үзеңә, гөнаһымы орма бәнем йөземә [ГМ.135]; Ғәфләт йоқысын бирмә безгә, илаһым [ГМ.12].

Баш килеш түбәндәге функцияләрдә килә:

а) субъект мөнәсәбәтен белдерә: қәрамәтдин башыңа таҗ орылды [Габди. 102];

ә) объект мөнәсәбәтен белдерә: Һуд йалаwыч әл күтәреб, қылды доға, чықты йил [Габди. 22]; Бинамазға қунақ барма [Габди. 13];

б) иялек мөнәсәбәтен белдереп I һәм II төр изафә барлыкка китәрә: Ир қолақын, хатын борынын берин-берин кисәрләр [Габди. 21];

в) бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән кулланыла: Үгез кебек үкертегез, Орма белән биргәләб [Габди. 20]; Йаwыз нийәт берлә килде кәғбәгә әсхбе фил [Габди. 22];

г) эндәш сүз буларак кулланыла: Мескин Ғәбди, йараған әйдә / Белмәзмү сән үлмәкең [Габди. 22]; Гөнаһым күп қөдрәт күзенә алма, сығындым, йарлықағыл, йә Алла [ГМ. 136]; Аның җәwер-wә-җәфасын тартғыл, и дуст [УИ. 100].

*Иялек килеше.* Истәлекләрдә иялек килеше, нигездә, *-ның/-нең* кушымчалары белән белдерелә, әмма *-ың/-ең* кушымчасы да очрый. Бу чор әсәрләр телендә иялек килешендәге *-ның/-нең* кушымчаларның ялгануы норма булып тора. Семантикасы буенча иялек килеше поэзия әсәрләрендә бер предмет, зат яки күренешнең икенче предмет, зат яки күренешкә ия булуын белдерәләр: Рузәнең wақтын белеб сәхәр торғыл [МК. 15б]; Бу гәүһәрнең қимматләрен белсә кеше [МК. 5б]; Дуадақның өне йуқ [МК. 19б]; Ул шәһәрнең шаһ қызы [МК. 4], Ул шәһәрнең шаһ қызы [МК. А64а.2]; китәрәйен сезнең йөзнең карасын [МК. А66а.13]; ғәзиз қолы иде бер Ходайның [МК. Б70б.4]; Бу дөнйаның үләксә тик, йуқ әсиғы [МК. 22б]; Ағачның башын киссәң, төбе қалыр, йарым, һай [Гс. 49]; Ғәлимләрнең хәлен сорғыл [Габди. 23].

XVIII йөз эш кәгазьләрендә, мәсәлән, шәхеснең кайсы авылныкы булуы документларда һәрвакыт иялек килеше ярдәмендә бирелә; документларның башлам өлгеләрендә теге яки бу шәхеснең тулы адресын бирү өчен дә иялек килеше формасы еш кулланыла һәм шулай ук иялек мөнәсәбәтен, шәхеснең теге яки бу авылга, яки төркемгә нисбәтен һ.б.ны белдерә (ачыкланган исем бу очракта, гадәттә, тартымсыз була) һәм иялек килеше хәзерге татар телендәге *-ныкы/-неке* кушымчасы белдергән мәгънәдә килә [Хисамова, 1981, б. 20].

*Юнәлеш килеше.* Мәүла Колый иҗатында юнәлеш килешендә кыпчак тибына хас *-ға/-гә; -қа/-кә* һәм угыз тибына хас *-йа/-йә; -а/-ә* күрсәткечләре кулланыла. Әсәр телендә юнәлеш килешендәге сүзләр эш-гамәлнең билгеле бер урынга яки объектка юнәлгән булуын белде-

реп киләләр. Мисаллар: Күб адәмне гүргә салды ошбу җиһан [МК. 1], Күрәр күзгә, ағызларә туфрақ тулғай [МК. 2], Тән-җан берлә теләйеб, Ахирәткә күчәрләр [МК. 2б], Иман әйтү үлгән қолға рәхмәт, дуслар [МК. 3б], Тән күзе Хақ әмрен күреб йулға күнсә [МК. 3б], Ғазраил тамырларға чәнгял орыр [МК. 4б].

Автор иҗатында юнәлеш килешенең яңгырау тартык белән башланган варианты саңгырау тартыкка тәмамланган тамыр яки нигезгә дә ялгана: Қош-қорт, хайwан, хәшәрәт Хақға қылур ғибадәт [МК. 20]; Ихласлықға булсын йырақ, йуқдыр хәтәр [МК. 11].

Мәүла Колый хикмәтләре һәм поэмаларында килеш кушымчаларының, кыпчак кушымчалары белән беррәттән, угыз вариантлары да кулланыла, әмма беренчеләре өстенлек итә: Күрер күзгә, ағызларә туфрақ тулғай [МК. 2]; Қорән уқыт, уғлың-қызың остазә wир [МК. 11б]; Остазә ит хезмәти, ғөмердер аз [УИ. 111].

XVII йөз язма истәлекләрендә әлеге килеш шулай ук *-ға/-гә, -қа/-кә* һәм *-а/-ә* кушымчалары ала. Мисаллар: қулға [Гс. 48]; адәмгә [УИ. 131]; күңелгә [ГМ. 44а]. Семантикасы буенча бу килеш формасы хәзерге әдәби телдәге кебек үк:

а) урын мөнәсәбәтен белдерә: Гүргә илтеб қуйубән [Габди. 16];

ә) кыек объект мөнәсәбәтен белдерә: Бу дөнйаға алдансағыз, ахирәткә қалынадыр [Габди. 16]; Дәфен итең чолғаб бүзгә [Габди. 13]; Йалсыз эшләр байға [Габди. 15]; Нәфсе шомға ойығанлар дүзәх эчрә алынадыр [Габди. 17].

б) максат мөнәсәбәтен белдерә: Бинамазға қунақ барма [Габди. 13]; Чақырмаңыз һәргиз ашқа [Габди. 14].

в) күчерелмә мәгънәдә килә: Намаз қылмай йөрегәннең хәле йаман керер төшкә [Габди. 14]; Гүзәл йарлар қулға төшсә – ғөмерлекдер, йарым, һай [Гс. 48]; Нәсыйхәтдин қолақға керсен бере [ГМ. 44б]; Күңелгә ал буны әй әхи [ГМ.44а].

Бу чор рәсми документларында юнәлеш килешенең *-ға/-гә, -қа/ -кә* формасы – 310 мәртәбә, ә көньяк төрләнешкә хас *-а/-ә* варианты 22 мәртәбә кабатлана. Юнәлеш килешенең көньяк (угыз) варианты, нигездә документларның башлам һәм бетем өлгеләрендә традицион калыпларда кулланыла [Хисамова, 1981, б. 93].

XVIII йөз әдипләре иҗатына да бу килеш өчен вариантлылык хас: әҗнәби+йә [Гс. 49], фәқир+ә [Гс. 70], дуслар+ә [ГМ. 68б], эш+кә [ГМ. 47а, 70а], тел+ә [ГМ. 59б], доға+ға [ГМ. 68б]. Мисаллар: Кешегә нәсыйхәт димәктән қалайым [ГМ. 45б]; Қолақ сал барча сүзгә, йегет

һәм қарый [ГМ. 44б]; Эшемезне йадә алсақ, йуқ күңелгә туласы [ГМ. 375б]; Ғәмәл қылмақ өчен күксемгә салдым [УИ. 78].

Статистика күрсәтүенчә, Мәүла Колый хикмәтләре телендә кыпчак тибына хас юнәлеш килеше кушымчалары *-ға/-гә; -қа/-кә* 22 һәм угыз тибына хас *-а/-ә* күрсәткечләре 14 тапкыр кулланылган. Юнәлеш килешендәге *-ға/-гә; -қа/-кә* кушымчаларның кулланылуы норма булып тора.

Тартымлы исемнәр юнәлеш килешендә Мәүла Колый иҗатында, нигездә, *-а/-ә* аффиксын ала: Һәр кеше Хақ нурына күзен ачса [МК. 19а], Хақ рәхмәте ул қолына булур булғай [МК. 33], Бер Алланың берлегенә раст итсә [МК. 3б], Мәүла Қолый, Хақ йулына башың салғыл [МК. 15б].

III затта, *-ына/-инә* аффиксыннан тыш, *-ыға* кушымчасы да кулланыла: Хақ қатыға уйлы туғры барыр булыр [МК. 3б]. Бу очракка мисалларны Г. Утыз Имәни иҗатында еш очратабыз: алдыға [УИ. 97], йөзигә [УИ. 82], сүзигә [УИ. 82], затыға [УИ. 97], бихишт алдыға [УИ. 97]. Мисаллар: Бу һидайәт йулиға илтәр сәни [УИ. 55]; шаһ морадның ишегигә йөз орыб [УИ. 59]; Бу ғәзизләр зөмрәсигә кермәгә [УИ. 61].

Г. Утыз Имәни иҗатында I зат берлек сандагы тартым белән төрләнгән исемнәр юнәлеш килешендә *-ға/-гә* кушымчасы алган очраклар да күп: сүзләремгә [УИ. 100], дустларымға [УИ. 100], үземгә [УИ. 100]. Шул ук биттә сүзләр+емә [УИ. 100] варианты да килгән. Мисаллар: Бәнем остадлығымға кәлде мөнкир [УИ. 143]; Кем ирсәни йибәрмәсләр йанымға [УИ. 72]; Идәрмен хөсне зан бу дустларымға [УИ. 100].

*Төшем килеше.* XVII–XVIII йөз поэзиясендә төшем килешенең *-ны/-не* һәм *-ы/-е* кушымчалары теркәлгән.

Кыпчак тибы төрләнеше *-ны/-не* кушымчалары ярдәмендә бирелә: ғәриблекне [МК. 23], күңелне [МК. 23б], дәмне [МК. 24б], адәмне [МК. 25], ғәләмне [МК. 25], йығачны [УИ. 129].

Төшем килешенең күрсәткече – *-ы/-е:* Сәҗдә өчүн бирде Алла ике тезе, сәҗдә йирин күрмәк өчүн ике күзе [МК. 16б].

Төшем килеше һәр очракта *-ны/-не* кушымчалары белән тәгьбир ителә һәм түбәндәге грамматик мәгънәләрне белдерә һәм туры объект мәгънәсендә килә: Төзер җирне үлән, йығачны йафрақ [УИ. 129]. Шулай ук вакыт мөнәсәбәтен дә белдерә: Мәүла Қолый, қийәмәтне белгел үзең [МК. 5]. Ф.М. Хисамова фикеренчә, бу чор рәсми эш кә-

газьләрендә төшем килешенең билгелелек төсмерен белдерү вазифасы әле хәзерге телдәге кебек анык билгеләнмәгән һәм бу килеш формасы билгеле объектны белдерү өчен дә, билгесез объектны белдерү өчен дә кулланылырга мөмкин [Хисамова, 1981, б. 72].

I һәм II зат берлек сандагы тартымлы исемнәрнең төшем килешенә мисаллар: Әwwәлеңне белмәгә һәм бер айәт йуқ, Ахырыңны [МК. 23], сәңа дир ул бәнем чөн жаныңи өз [УИ. 114], һаwа берлә һәwәсне қуйғыл имди, йаман фиғылләреңне йуйгыл имди [УИ. 118], йандырыр тәбәссемлә ғәләми, Сабры wарым кичә белмәз ошбу хәстә хәлеми [МК.], Мәгәр бәнем өнемне ишетмәссез [ГМ. 70а].

III зат берлек сандагы тартымлы исемнәр төшем килешендә кыпчак төрләнешенең *-ын/-ен* аффиксларын, ә угыз төрләнешенең *-ыны/-ене* аффиксларын алалар: Ул гәүһәрнең қимматене тикмә белмәз [МК. 32б], Мөэминләрнең кәғбәсене боздырыр [Гс. 66], Ата-ана хезмәтене бән гөнаһкяр қылмадым [Гс. 70], сән аларның сүзени тотма зинһар [УИ. 114], Рәсулулла хәдисен әйлә әда [УИ. 114]. Мисаллар: эшене [МК. 25б], тешене [МК. 25б], былбылларын [МК(п).63а], сыйфатыны [МК(п). 65а], wажибларыни [УИ. 114.], эшене [Габди. 13], эшләрене [Габди. 13], ашын [Габди. 15], хезмәтене [Гс. 70], малын [УИ. 127]. Мондый очраклар Габделмәннан Мөслимов иҗатында да шактый: Ахырыны айғучы инде әхәд [ГМ. 43б]; Хисабламай йатырыны йир қочыб [ГМ. 47а]; Йәнә айларның балаларыны wә ғәзизләрен [ГМ. 49б]; Телеңдән салма Алла атыны / Әда қыл пәйғәмбәр сөннәтене [ГМ. 67а].

Статистик мәгълүматлар күрсәтүенчә, кыпчак тибына хас төшем килеше кушымчалары *-ны/-не* Мәүла Колый хикмәтләре телендә – 36 һәм угыз тибына хас *-ы/-е* күрсәткечләре 24 тапкыр кулланылган. Төшем килешендәге *-ны/-не* кушымчаларының кулланылуы норма булып тора, ә тартымлы исемнәрнең төшем килешендә шулай ук кыпчак формасы өстенлек итә.

*Чыгыш килеше.* Чыгыш килеше Мәүла Колый иҗатында борынгы уйгыр әдәби теленнән үк килә торган һәм күп кенә төрки һәм татар истәлекләре өчен хас булган *-дыйн/-дин* формалары аша белдерелә. Хикмәтләрдә чыгыш килешендә килеп, *-дин* кушымчасы алган сүзләрнең саны – 454, ә *-дан* кушымчалыларының бары тик 6 гына булуы мәсьәләне ачык күрергә мөмкинлек бирә, саңгырау вариантлы *-тин* кушымчасы бер урында *ис* сүзе белән килә: Ул суфилық миwәсендин татған кеше, Җазебә улыб, истин китәр дөнйа эше [МК. 7]. Әлеге саннар исемнәрнең чыгыш килешендә бик еш кулланылуын күрсәтә.

Тикшерелә торган поэтик әсәрләрдә чыгыш килешенең борынгы уйгыр формасы *-дин* актив кулланыла, исемне фигыльгә һәм башка сүз төркемнәренә ияртеп килә. Чыгыш килешендәге исем эш яки хәлнең чыгыш ноктасын белдерә: қулдин [МК. 23], тәхетдин [МК. 23], көндин [МК. 23б], хақдин [МК. 24], җандин [МК. 24б], ирәнләрдин [МК. 31], атадин [Гс. 49], атамдин [ГМ. 84], адәмдин [УИ. 118].

Тикшерелгән әсәрләр телендә *-дан* формасы да очрады, әмма ул системалы түгел: Җандан җөда булса бу тән хәраб анда [МК. 2], тотды безне йоқудан [МК(п). 68а]. Г. Утыз Имәнинең «Мөһиммәт-ез-заман» поэмасында Йәнә бәғзеси ғалим бәғзе надан, карап белсәң нә була имди бондан [УИ. 138] шигъри юлларында рифма таләбе белән *-дан* кушымчасы кулланылган. Габделмәннан Мөслимов иҗатында *-дан* варианты чордашлары белән чагыштырганда активрак: тәмуғдан [ГМ. 43б, 43б], сүземдән [ГМ. 44а], эшләрендән [ГМ. 44б], башдан [ГМ. 44а], китаблардан [ГМ. 45а], җиһандан [ГМ. 69б], күңлемдән [ГМ. 69ба], күңелдән [ГМ. 69б] һ.б.

Чыгыш килеше кушымчасы шагыйрь текстларында өч төрле язылышта килә: 1) دان 2) دن 3) دين . Кулъязмада соңгы вариант азга гына өстенлек итә. Габделмәннан Мөслимов иҗатына *-дан* кушымчасының актив кулланылышын, әсәрдә булган башка үзенчәлекләрне дә истә тотып, госманлы төрекчәсенең йогынтысы дип аңлатабыз.

XVIII йөз язма истәлекләрендә чыгыш килеше кушымчасының барлык вариантлары да күзәтелә: *-дыйн/-дин* һәм хәзерге татар әдәби теле өчен хас булган *-дан/-дән* формалары аша белдерелә, шулай ук *-тан/-тән/-тин* саңгырау вариантлары да очрый: Йарымдин хәбәр килмеш [Гс. 50]; Гүрдин бергә қубғучы [Гс. 50]; Бу ғәрибдин йуқ ғибәдәт [Гс. 51]; Бу хәбәрләр пәйғәмбәрдин йәдкәр қалған имди безгә [Габди. 13]; Дөнйа малын ала күрмә хәрәм йирдин сырмаб, қармаб [Габди. 22].

Чыгыш килеше кушымчасы документларда, башлыча, яңгырау вариантта килә, язуда ассимиляция бөтенләй чагылмый диярлек. Аерым очракларда гына *-тан* яки *-нан* вариантын очратырга мөмкин. Мәсәлән: ...Чаллы авылыннан килгән каптан (капитан. – *Ф.Х.*) [Хисамова, 1981, б. 112].

Борынгы *-дин* уйгыр формасын куллану бу чор әсәрләренең үзенчәлеге булып тора һәм борынгы традицияләрнең саклануын күрсәтә.

*Урын-вакыт килеше.* XVII–XVIII гасыр истәлекләре телендә урын-вакыт килеше *-да/-дә* аффикслары аша бирелә: күкрәкдә

[МК. 23б], күңелдә [МК. 24], йулында [МК. 24б], күздә [МК. 24б, 35, 35б], күкдә [МК. 8, 8б, 13, 15б], дәрәхтендә [МК. 43б], тәмуғда [МК. 32], аwылында [ГМ. 69б], китабларда [ГМ. 46а], қулында [Гс. 43].

Урын-вакыт килеше объектның урынын, вакытын яки эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын белдерергә мөмкин: 1) Йанчыкында теллә әхмәр чук дорыр [УИ.55]; Йир йөзендә күб-күб фәсад булыр ирмеш [МК. 7б]; 2) Ахыр дәмдә рузи қылсын мәңа иман [МК. 2].

III зат берлек сандагы тартымлы исемнәр урын-вакыт килешендә *-ында/-ендә* аффиксларын алалар: Қыш көнендә үләнләр йирдә черүр [МК. 14б], Йаз көнендә болыты аз – чуақ ула [МК. 14б], қәрендәшләрем қулында [Гс. 42].

XVIII йөз истәлекләрендә исемнәр алты төрле килеш формасында киләләр һәм, асылда, төньяк төрләнеш тибына караган түбәндәге кушымчаларны алалар:

| Килешләр | Кушымчалар |
|---|---|
| Баш килеш | Ø |
| Иялек килеше | -ның/-нең, -ың/-ең, -уң/-үң |
| Юнәлеш килеше | -ға/-гә, сирәгрәк -ка/-кә, -а/-ә |
| Төшем килеше | -ны/-не, -ы/-е |
| Чыгыш килеше | -дан/-дән, -дыйн/-дин,<br>бик сирәк -тан/-тән, -нан/-нән/ |
| Урын-вакыт килеше | -да/-дә |

Көньяк төрләнеш тибына караган кушымчалар аерым әсәрләрдә, хәтта аерым әдиләрнең билгеле бер әсәрләрендә, рәсми документларның башлам яки бетем өлешләрендә, шул чор рәсми документлар стиленә хас тотрыклы сүзтезмәләрдә һәм традицион тәгъбирләрдә [Хисамова, 1981, б. 119] очрыйлар. Казан ханлыгы чорының төп ядкәрләре телендә сирәк кулланылган бу төр кушымчалар XVII–XVIII гасыр поэзиясе текстларында арта.

Әлеге чор поэзиясе телендә бер килеш урынына икенче килешне куллану очраклары шактый күп: Белдүкемне сөйләйүбмән нәфғечөн шәйх wә шәбаб [УИ. 15]; Кереб җәннәт қочарыз қызлары хур [УИ. 3-15] мисалларында баш килеш юнәлеш килеш урынына килә.

Тикшерүләр нәтиҗәсе шуны күрсәтә: иялек килешендәге *-ның/ -нең* кушымчаларның ялгануы норма булып тора, юнәлеш һәм төшем

килешләрендә кыпчак тибы төрләнеше актив кулланыла һәм бу төр кушымчалар шулай ук норма тәшкил итә. Чыгыш килешендәге борынгы уйгыр *-дин* формасының актив кулланылуы күзәтелә. Урын-вакыт килешенең яңгырау варианты *-да/-дә* кулланыла.

Шулай итеп, XVII–XVIII гасыр истәлекләре телендә килеш белән төрләнештә, нигездә, ике төрле кыпчак һәм угыз төрләнеше күзәтелә. XVIII йөз әдипләре иҗатында, алдагы чор истәлекләре белән чагыштырганда, угыз вариантларының активлашуы күренә. Бу бигрәк тә Габделмәннан Мөслимов, Габдерәхим Утыз Имәни иҗатында чагыла.

Тартымлы төрләнештә, хәзерге татар телендәге кебек үк, төньяк һәм көньяк төрләнешләргә караган аффикслар катнаш хәлдә кулланыла, һәм тартымлы төрләнеш тулысынча тартымсыз төрләнешкә нигезләнми.

| Килешләр | Кушымчалар |
|---|---|
| Баш килеш | Ø |
| Иялек килеше | -ым-нын, -ың-ның, -ы-ның |
| Юнәлеш килеше | -ым-а, -ың-а, -ын-а |
| Төшем килеше | -ым-ны, -ың-ны, -ын, -ыны |
| Чыгыш килеше | -ым-дан, -ым-дин, -ың-дан, -ың-дин, -ы-дан, -ы-дин |
| Урын-вакыт килеше | -ым-да, -ың-да, -ын-да |

Мисаллар: Күб сүземдин ары [ГМ. 66б], Телеңдән салма Алла атыны [ГМ. 67а], Рәсулулла хәдисене аңламайын ҡалмаңыз [Гс. 30б], Күрдем байның күчене / күч эчендә йүчүне [Гс. 31а], Ҡашына ҡәләм йазадыр [Гс. 31а], Алғыл бәне ҡуйныңа [Гс. 31б], Тәуфиҡлы ҡолларыңдан бәңа булмаҡ [ГМ. 67б], йахшы сүздин ғаҡлыңи хәйран ҡылыр [УИ. 60], бернәчә гүшт ҡазаныңға саласән [УИ. 60], Һич кешенең сүзигә салмас ҡолаҡ [УИ.1-60], Ул муллаларның мәкрегә төшде [УИ. 2-20, 21].

Димәк, тикшерелә торган истәлекләр телендә аерым очракларда төшем килеше тулы вариантта да, кыскартылган хәлдә дә, юнәлеш һәм чыгыш килеше кушымчалары *-н-* авазыннан башка да кулланыла.

Юнәлеш килешенең хәзерге әдәби телгә хас *-ына* варианты төп кушымча булып тора һәм, *-ыға/-ынға* вариантлары белән чагыштырганда, күпчелекне тәшкил итә.

Чыгыш килешендә *-ындин/-ын-дан* формасы өстенлек итә, ә *-ыдан/-ыдин* варианты сирәк очрый.

Чыгыш килеш кушымчасы *-даин/-дәин* вариантында кулланылган очрак та бар. Бу вариант рәсми документларга хас: ...һәм ул Бөре қәлғасындаин қайтып төшдек Суқайаз авылына... /189 б. [Хисамова, 1981, б. 72].

Тартымлы төрләнештә сирәгрәк традицион әдәби тел өчен хас уйгыр формалары да урын ала: юнәлеш килеше – *-ыға/-игә,* чыгыш килеше – *-ыдан/-идән.*

*Хәбәрлек категориясе.* Текстларда хәбәрлек категориясенең I зат күрсәткече булып *-мән* аффиксы килгән очраклар бар, әмма алар системалы түгел, сирәк очрый: Ғасый мән диб, өмид кисеб, хақдин бизмәс [МК. 43]; Ничек колмән димәсмез булсақ адәм [УИ. Мзз. 113]; сән уйларсән егетмән үлмәгәймән [УИ. Мзз. 114].

II зат мәгънәсе *-сән* аффиксы ярдәмендә белдерелә: Илаһи, ғәләмләрнең солтанысән [МК. 16]; Тәғәтләрдин Хақ ғәни сән, Солтанларның солтаны сән, Мөэминләрнең иманы сән [МК. 20б].

Текстларда III зат мәгънәсе ике төрле ысул белән тәгъбир ителә: а) *торыр* сүзе ярдәмендә: Унсигез мең ғәләм торыр [МК. 9б]; ә) *-дыр/-дер, -дур/-дүр* кушымчасы белән дә белдерелә ала. Сүз саңгырау тартыкка тәмамланса да, аңа яңгырау тартыктан башланган аффикс ялгана һәм рәт гармониясе саклана: «Ляиляһиилля Алла дисә Хақ қолыдыр, Низ йәнә Мөхәммәд Рәсүлалла өммәтедер, Баш ийеб, сәҗдә қылса ислам динедер [МК. 9б] Хақ қолыдыр хаҗ ғөмери эстәб китсә / Хақ қолыдыр сәҗдә қылыб, Алла дисә [МК. 9б]. Мисаллар: аwылыдыр [ГМ.69а], аслымдыр [ГМ.70а], атумдур [ГМ.69а], исмедер [Гс.30а].

Мисаллардан күренгәнчә, әсәрләр телендә хәбәрлек кушымчаларының тартымлы исемнәргә ялгану очраклары да күзәтелә.

## 4.2. Сыйфат

XVII–XVIII йөз әсәрләре телендә кулланылган сыйфатлар, аерым алганда, зат һәм предметларның тышкы сыйфатлары (*арық*), кешенең эчке үзенчәлекләре (*бозық, рәхимсез, ахмақ*), пространствога бәйле мөнәсәбәтләр (*йырақ, кыска, озын*), предметларның төсе (*ак, кара, қызыл, сарығ*), тәме (*ачығ, татлы, татлиғ,*), физик халәте (*териг, үлек*), формасы (*нәзик*) һәм башка билгеләр керә. Мисаллар: Габделмәннан

үзедер қара йөз [ГМ. 69б]; Мәүла Қолый, Хаққа қол бул, моңлуғ башың [МК. 12б]; Га уласән ике ғәләм йөзе ак [УИ. 37].

*-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчалары һәм төрки-татар чыгышлы, һәм гарәби, фарсы чыгышлы сүзләргә ялгана: Бәнем күңелем улды, бер қарарсыз, ғәмәлем бәнем тәмам йарақсыз. / Мин ғәриб ни қылайым ғәмәлсез, Сүзләдем сүзләремне чарасыз [ГМ. 69б]; Қайғылы мөселман, йийәмез хәрам аш [ГМ. 46б]; Хаққа қоллық қылмадым, гөнаһлы гақ [ГМ. 61а]; Тәүфиқлы қолларыңдан бәңа улмақ [ГМ. 68а]; Әгәр чықса җиһанә қуәтле бада [ГМ. 45а]; Рәхим қыл, рәхимле сән, йа Барый [ГМ. 52б].

Фарсы *би-* һәм *на-* префикслары белән ясалган сыйфатлар да шактый: Хақ қашында бихисап қылдым гөнаһ [ГМ. 63а]; Бу дөнйада бармы миндәй биһөнәр [ГМ. 69б]; Биwафадыр ошбу дөнйа улмайа улдасы йар [Гс. 64]; Wәҗиһшәм қылдың биһуш [Гс. 65].

Сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе морфологик-синтаксик юл, ягъни чыгыш килеше кушымчасы аша бирелә һәм бу очракта сыйфат *-рак* кушымчасын алмый: Оҗмахының шәраблары ақдыр сөтдин, / Суықлықы суық торур, белгел, боздин. / Ләззәте артук торур шәкәр-балдин [МК. 14а]; Күр үзендин олуғны һәм кечекне [Мзз. 3-52], Беләмен дир ғәми ғәлимдин артық [Мзз. 18-6].

Төс белдергән сыйфатларда артыклык дәрәҗәсе кабатлау юлы белән белдерелә. Мәүла Колый иҗатында бер урында *каб кара* формасы бирелә: Тыш сурәт ақ, бу күңел қаб қарадыр [МК. 41б]. Бу рәвешле белдерү кайбер башка сыйфатларга да хас. Г. Утыз Имәни иҗатында *туб тулы* мисалы теркәлгән: туб тулыдыр сандықы белгел и йар [УИ. 106].

Сыйфатланмыштан башка килгән сыйфатлар җиңел исемләшәләр һәм, сыйфатланмышның грамматик категорияләрен үзенә кабул итеп, килеш, тартым, сан белән төрләнә башлыйлар: Йахшыларға улыңыз йахшы, / Йаманға улмасын күзеңез wәхши [ГМ. 66б].

Мәүла Колыйның лирик герое да психологик яктан тирән кичерешләр кичерә, яшәеш мәгънәсе, асылы, гаделлек һәм гаделсезлек, нәфес һәм юмартлык һ.б. шундый кыйммәтләр турында уйлана. Гомумән, ул матди кыйммәтләрдән өстен, шагыйрь кешеләрне Аллаһ мәхәббәтенә лаек булу яки булмау ягыннан аера. Мәсәлән, ул тәмәке тартуны Аллаһтан ерагайта торган гамәл буларак карый һәм аны *нәпакый* (пакь булмаган), *нәҗес* синонимнары белән сәнгатьчә сурәтләп-ачыклап бирә: Ләғин шәйтан хезмәтедер, бел, тәмәке,/

Тәмәкене тартмыш кеше, бел, нәпақи./ Сыйфаты охшар аның нәҗес хуки [МК. 14].

*Яман* һәм *харам* сыйфатлары мөселманнар эшләргә тиеш булмаган эшләрне белдерә: Башқа ғақыл бирде Рәхман, үзең белгел, / Тот хәләлне, харам эшдин йырак торғыл [МК. 17]; Йаман эшдин, күрсә, йырақ булсын дийү [МК. 17].

XVIII йөз поэзиясе телендә сыйфатлар ешрак кулланыла. Габдессәләм иҗатында кешегә (мәсәлән, кызга) мөнәсәбәтне белдергән сыйфатлар чагылыш таба: Ай кеби йақты йөзең һәм бал кеби татлы сүзең, Салды бәне ғишық утыға шул ике қара күзең [Гс. 67]; Сәнең зифа буйларың [Гс. 58]; Сарғайыбдыр бән фәқирнең гөл тик қызыл йөзләре [Гс. 58]. Кешенең холык-фигылен белдергән билге сүзләре образларга характеристика бирергә, аларны төрле яклап ачыкларга ярдәм итә. Без иҗатларын тикшергән шагыйрьләр аларны, еш кына, үзләренә карата файдалана: Бары бозық эшем қылдым тәфәккер [ГМ. 48б]; Бозық сүзләр булды бәңа ләтыйфә [ГМ. 45б]. Г. Мөслимов әсәрендә Аллаһның эпитетлары күп тапкырлар искә алына: Рәхим қыл бәңа сән, йа Нафиғ, Йа Моғтый, йа Мәнар, йа Бәриғ. Рәхим қыл, йа Нәwwар, йа Һадый, Йа Wарис, йа Рәшид, йа Бақый. / Рәхим әйлә бәңа сән, йа Сабур, Рәхимле сән, йа Садыйқ, йа Остаз [ГМ. 52 б].

Шул рәвешле, XVII йөз поэзиясе Мәүла Колый хикмәтләре белән билгеләнә, Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъяр поэмалары белән чагыштырганда, сыйфатлар бу чорда мәгънәви яктан үзенчәлеклерәк кулланылышка ия. Бу, күрәсең, Мөхәммәдъяр әсәрләренең дөньяви эчтәлеге һәм авторның сәнгатьчә эшләнеш мәсьәләсенә игътибар итүе, ә Мәүла Колыйның яшәеш мәгънәсе, асылы, гаделлек һәм гаделсезлек, нәфес һәм юмартлык һ.б. шундый кыйммәтләр турында уйлануы белән аңлатыладыр. XVIII гасыр поэзиясендә сыйфат сүз төркеме сан ягыннан күбрәк кулланыла һәм аларның семантикасы да төрле.

## 4.3. Рәвеш

Рәвеш килеп чыгышы һәм составы агыннан үзенчәлекле сүз төркемнәренең берсен тәшкил итә. Исемнәрнең төрки чыгышлы катып калган килеш формалары, сыйфат һәм хәл фигыль формалары да рәвеш ролендә килә ала. Моннан тыш, шагыйрьләр гарәп һәм фарсы

рәвешләреннән иркен файдалана, шулай ук гарәби чыгышлы төп юнәлештәге сыйфат фигыльләрнең да рәвеш функциясендә килүе күзәтелә.

XVII–XVIII йөз әсәрләре телендә төрки-татар чыгышлы рәвешләр, үзләренең лексик-грамматик мәгънәләренә карап, берничә төркемгә бүленәләр.

Күләм-чама рәвешләре эш-хәрәкәт яки билгенең билгеле һәм билгесез күләмен белдереп киләләр: күб [МК. 1б, 7б, 7б, 7б,10,]: Бездин борун күб җанлар золмәт гүргә бардылар [МК. 29б]; чуқ [12б, 13б, 14б, 38б]: Йақтысы аз, қаранғусы чуқ чуқ булур [МК. 14б]; аз [14б, 14б, 24, 39]; төне-көне эчдең аны райған булыб [МК. 30б]; Төн-көн сәнең сағлығыңны Хакдин теләр [МК. 30б]; озақ [МК. 38]: Шәйех мәкән илләре, озақ торур йуллары, буш [МК. 15, 24, 37, 38, 39, 44, 46]: Килер үлүм, намаз қылмай тормағыл буш.

Хәл рәвешләре процессның башкарылу урынын, вакытын, сәбәбен һәм максатын белдереп киләләр. Бу чор язма текстларында да хәл рәвешләренең вакыт рәвешләре, аерым алганда, *кичә, кичен, көндез/көндүз, хәзер, кышын, йазын,* рәвешләре актив: Кәчә-көндез тәүбә қылыб, белгел [МК. 28б]; Хақ ешендә ғөмрең кәчәр көндөз кәчен [МК. 42]; Остадымның доғасы төш булса йәрин [МК. 3б].

Бу чор әсәрләре телендә, еш кына, гарәп һәм фарсы чыгышлы рәвешләр кулланыла. Мәсәлән, Мәүла Колый иҗатында алынма рәвешләрдән түбәндәгеләр күзәтелә: *һәба* – бушка, файдасызга [МК. 33б]: қоңғыз қорт тик дөнйа өчүн һәба қазғана; һәман – һаман [МК. 8б, 9, 10б, 14б]: қари кеше мисле һаман қыш тик була; *һәргиз* – беркайчан да [МК. 2, 3, 7б,10, 23, 30б, 39, 46]: Ихлассызға Хақ суфилық һәргиз бирмәз; *һәрдәм* – һәрвакыт [Кадирова, 1997, б. 107].

XVIII йөз поэзиясе телендә дә рәвешләр кулланылышында, нигездә, саналган үзенчәлекләр саклана. Шунлыктан XVIII йөз шагыйрьләре иҗатыннан мисаллар китерү белән чикләнәбез: Тәғәт қылғыл кәчә көндез, йайын, қышын, йазын, көз [Габди. 28], Йөремәгел коры, буш [Габди. 18]. Шулай ук рәвеш ясагыч кушымчалар белән рәвеш ясау активлаша бара: Синдин ула ташдай күңел йомшамақ [ГМ. 68б]; Бағлай қоштай талпыныр қызны күрсә [Гс. 44]; Йәшлегемдә изге йулға дүнмәдем, Йарағанча изге эшкә күнмәдем [ГМ. 53а].

## 4.4. Сан

Сан исемнәре үзләренең төп функцияләрендә кулланылалар, ягъни микъдар төшенчәсен, предметларның данә исәбен белдерәләр. Тикшерелә торган әсәрләрдә микъдар саннары очрый. Микъдар санының махсус кушымчалары юк һәм башка сан төркемчәләре ясалуда төп нигез булып тора. Мәсәлән, Мәүла Колый иҗатында *алты* [МК. 14б, 14б, 25]: Бу алты пәйғәмбәри таң ешләренә гәрчә кәлде һәр waiиѓа башларына; *ике* [МК. 4б]: Ике қулны бирде Алла қүәт илә; икесе [МК. 15б, 27б]: Дин йулында икесе – ике рәшид; ду [МК. 18б, 22, 38б]: Ду җиһанда һәмраһ бул; дүрт [МК. 1б, 9б, 25, 29б, 30б, 31б, 31б]: Мостафаның дүрт йар илә әүладлары; *йите* [МК. 12б, 19, 20б, 21, 23, 31б, 34б, 37б]: Йите қат күкдин әғлә миғраҗ китде; *йитмеш* [МК. 7, 8б,38]: Йитмеш аршин су йуқары андин кәчә; биш йөз [МК. 31, 31]: Андин булды биш йөз уғлан, биш йөз ғәйәл; *сәкез* [МК. 38б]: Сәкез җәннәт ечрә сәйран қыланлардин әйлә безне; *сиксән сәкез* [МК.]: Сиксән сәкез ирде тарих ул көн megң дә; *туқыз* [МК. 30б]: Туқыз ай үткәндин соң тифел уғлан бу дөнйаға туға килдең, солтан булыб.

Әсәрләрдә аергыч ролендә килгән саннарга махсус ачыклагыч саннар иярә. Алар, гадәттә, аергыч белән аерылмыш (сан һәм исем) арасында әйтеләләр. Бу сүзләр саналмыш предметының сыйфаты белән ярашкан булалар һәм, нәтиҗәдә, алар телдә аерым категория сүзләргә генә хас булган нумератив билге булып урнашалар. Нумератив сүзләрдән әсәрдә вакыт исәбен белдергән *көн, ай, ел* сүзләре кулланылган: туқыз ай [МК. 30б], бер көн [МК. 3], қырық йыл [МК. 8].

XVIII йөз шагыйрьләре дә саннарга еш мөрәҗәгать итәләр. Габдессәлам иҗатында кулланылган микъдар саннары әйбернең микъдарын белдерәләр: Әгәр йабсаң кешедин бер ғәйебне, Хода йабқай сәңа һәм мең ғәйебне [Гс. 46]; Қашың берлә күзеңә, йөз мең алтын үзеңә. / Җаным фида қылырмын бер кәлимә сүзеңә [Гс. 47]; Ике дохтәр оршышадыр йегет өчен, һай [Гс. 47]. Г. Утыз Имәнинең «Гъәуариф-ез-заман» поэмасында икенче, өченче, түртенче, бишенче, алтынчы, йиденче тәртип саннары урын ала [УИ. 93–95], шул поэмада ук автор Адәмнең начар эшләрен ундүрткә кадәр саный. Поэмада *йегерме йите* саны да килә.

## 4.5. Алмашлык

Алмашлыклар кешелек җәмгыятендә абстракт фикерләү дәверендә барлыкка килә, чөнки бу сүз төркемнәренең төп үзенчәлеге булып, гомумиләштерү тора.

Безнең өйрәнү объекты булып торган истәлекләрдә зат, күрсәтү, сорау һәм билгеләү алмашлыклары кулланыла.

*Зат алмашлыклары.* Текстларда түбәндәге зат алмашлыклары очрый: *мән, мин, бән, сән, син, ул, без, безләр, сез, сезләр алар, анлар*.

Статистик мәгълүматлар күрсәткәнчә, Мәүла Колый иҗатында *мән, мин, бән* формалары арасында *мән*, *бән, мин*, ә *анлар* һәм *алар* формаларыннан *анлар* өстенлек итә. Алмашлыкларның килеш белән төрләнешендә кыпчак тибы кулланыла: Хаққа шөкер қылмақ фарыз сәңа, мәңа [МК. 14б]; Рахмән изем қазый булыб мәндин сорса [МК. 2]; Бу җиһанда туғмады мәндин йаман [МК. 2]; Нәфес илә шәйтан мәңа бирде йаман [МК. 2]; Ахыр дәмдә рузи қылсын мәңа иман [МК. 14б].

I зат күплек санда *без* алмашлыгының төрләнешендә угыз формативлары да (безем, безә, бези) барлыгын күрдек, әмма алар сан ягыннан күпчелекне тәшкил итми. Мәсәлән, М. Колый иҗатында *безем* – 1, *безнең* – 0, *безгә* – 39, *безә* – 1, *бези* – 2, *безне* – 16. Бу автор әсәрләре телендә I зат күплек сан алмашлыгының борынгы *безләр* формасы да кулланыла: безләргә тәүфиқ насыйп қылсаңмы [МК. А70а.12].

XVIII йөз поэзиясендә угыз формалары шактый активлаша төшә. Мәсәлән, Габделмәннан Мөслимов иҗатында *мин* алмашлыгының *бән* варианты ешрак күзәтелә. *Бән, бәнем, бәңа, бәне, бәндин* формалары бу чорның барлык авторлары иҗатында да өстенлек итә: мәнем дик улмағыл, қәрдәш ыруғ [ГМ. 65б], бәнем исмем кем икәнен белсенләр / бәнем өчүн изге доға қылсынлар [ГМ. 68б]; ғөнаһымы бәрмә бәнем йөземә [ГМ. 47б]; Бән қолың йөредем йулдин азыб [ГМ. 48а]; Бәне мәхрүм әйләсәң [Гс. 31б].

*Сез* II зат алмашлыгы аерым төркемгә һәм билгеле бер затка олылап, хөрмәт белән мөрәҗәгать иткәндә кулланыла: Дыңласаңыз разын сезгә ачарбыз, аһ [МК. 10]; Андин бизеб, сүзне сезгә сачарбыз, аһ [МК. 10]; Инде сезләр сорасаң [Гс. 30а]; Эше асандур сезә, безә [МК. А70а.9]; Китәрәйем сезнең йөзнең қарасын [МК. Абба.13]; Кемдер ул кем сезни ашқа чарлағай [УИ. Тг. 66].

*Анлар* һәм *алар* вариантларының беренче формасы өстенлек итә, алар берничә очракта гына күзәтелде: Көн дә алар тиңдәшеңез [Габди. 18]; йәнә анларның балаларыны wә ғәзизләрен [ГМ. 59б].

Мәүла Колый хикмәтләрендә һәм поэмаларында кулланылган зат алмашлыкларынын статистик күрсәтмәсе:

| | Хикмәтләр | «Береккәннәр сыйфаты» | «Хәләл нәфкә эстәгәннәр сыйфаты» |
|---|---|---|---|
| | Зат алмашлыклары | | |
| | Берлек сан | | |
| I зат | мән – 152<br>мин –3<br>бән – 10 | мән – 16,<br>мин – 3 | мән – 7,<br>мин – 1 |
| II зат | сән – 178<br>син –2 | сән – 21 | сән – 8 |
| III зат | ул | ул – 8 | ул – 2 |
| | Күплек сан | | |
| I зат | без – 67<br>безләр – 1 | без – 11<br>безләр – 1 | без |
| II зат | сез – 2 | сез – 4 | сез |
| III зат | анлар – 92<br>алар – 2 | анлар – 2 | анлар |

*Күрсәтү алмашлыклары.* Ул, бу, ушал, ошбу, шул, анда, андағ, монда, мондағ, монча, анча, менә: Ул кеше туқ / үзгәләр ач бу көн менә [МК. 14б]; Бу үлүм терекләргә киләседүр / Бу тән милке җандин җөда буласыдур / ошбу эшләр барча җанға буласыдур / Берин -берин илтә торыр ошбу үлүм [МК. 15].

*Бу* алмашлыгының төрләнгән очракларда Мәүла Колый хикмәтләрендә *моның, моны, мондин, монда* формалары кулланылганлыгын күрдек: монда [1б, 2, 2, 2б, 3, 5, 6б, 6б, 32, 34, 34, 36, 36, 36б, 36б, 37, 37, 37, 37, 37, 37, 37, 37б, 46б, 46б, 46б, 46б, 46б, 46б, 46б, 47, 47, 47, 47, 47, 47, 47: Ахирәтнең ешен монда қылың, дуслар; мондағ [23, 34, 36б]: Игенченең эше мондағ, белүр булсаң; мондин [4б, 4б, 29, 42б]: Мондин китеб, гүр өйенә барасыдур; монлар [4б,10б]: Монлар қылған доға сиңа булмаз тимәң; моны [2, 4,16, 37б]: Хақ рәхмәте күкдин инәр, белгел моны; моның [4б,14]: Шәриғәтдә кисмәк торур моның телен

[МК. 4б]. Мәүла Колый хикмәтләрендә *андағ* һәм *мондағ* формаларына караганда *анда* һәм *монда* вариантлары активрак.

М. Колый әсәрләрендә *шул* алмашлыгы түбәндәгечә урын ала: шул [8, 10, 10, 12б, 12б, 14, 14б, 23б, 25, 25, 31б, 32б, 33, 39б]: Шул wақытда Хақ дидарын күрмешдүр ул; шул+дур [13]; шундағ [23, 33]; шундин [4]; шуның [22б] [Кадирова, 2003, с. 112].

XVIII йөз әдипләре теленнән дә әлеге алмашлыкларга мисаллар китерә алабыз:

*Бу*: Хақ йулында йуктыр мондай азан [ГМ. 46а], Күңелемә алайым мондин арый [ГМ.59б].

*Шул*: Шул Габделмәннан үзедер қара йөз [ГМ. 69б]; Шулдыр мәңге тәмуғда қалмышым / Йа Рәсулулла, мөбарәк исмең – Мөхәммәд / Шул исмең хөрмәте өчен қыл шәфәғәт [ГМ.53б]; Шул олуғ исемләрең хөрмәтенә [ГМ. 53а].

*Сорау алмашлыклары*. Кем, қайда, қайу, қайусы, нәчә, нәчүк, нәрсә, қайу [МК. 40, 41, 41, 44б]: Ул хезмәтче қайу тийү бәндин сорсаң, җаwаб әйтәйен, аңла белсәң; қайда [МК. 25]: Мәккә йулы қайда тийү, естәб китте; қани [МК. 2, 4б, 4б, 6б, 6б, 7, 7, 20б, 23, 30, 32б, 42б]: Ғәләм халқын күзгә алмаз, мән, мән тийүр, қани ғәлим ихлас қылур қулы йуқдур; нәтәк [МК. 18, 18, 23б, 23б, 23б, 35, 35, 35, 39]: Нәтәк йуwыб ақартайым, суы йуқдур; нәрсә [8б] : Йәш нәрсә қалмыйча, кибеб күмер булғай; нә [МК. 2, 2, 4б, 5, 5, 10, 14, 14, 20, 20, 20б, 21, 24б, 25, 25, 27б, 32б, 38б, 39б, 43, 44, 46, 46, 46, 46, 47, 47, 47, 47б, 47б, 47б, 47б, 47б, 47б]: Күңел сәндин айрылмайдур, нә қылайын; нәчә [МК. 1б,1б, 4, 6, 15, 15, 18, 24, 24, 30б, 31, 33, 34б, 40, 45]: Хикмәт әйтүр нәчә хәлең булур микән; нәчүк [1б]: Мәнем хәлем ул көн нәчүк булур микән.

*Билгеләү алмашлыклары:* җөмлә, җәмиғ, қамуғ, бар, барча, бөтен, һәммә, һәр, һәркем, һәрнәрсә, һәрни, һәрқайусы, һәрбер: Барча Адәм үлеб барыб, гүргә керүр [МК. 14б]; Үлүк кеше, һәрни дисәң сүз аңламаз [МК. 27б]; Һәрни қылса изем қылур ул көн безгә [МК. 33б].

*Юклык алмашлыклары*. М. Колый хикмәтләрендә һич, һичкем, һичнәрсә, һичбер алмашлыклары очрый: Гарибләрне һичбер адәм алмаз санға [МК. 23]; Мал йыймақдин һичбер файда булмаз ирмеш [МК. 6б]; Ахырыңны һичкем белмәс [МК. 20б]; Һичкем сәңа хаҗәт бәхәс қылмақ йукдур [МК. 20б].

Бу төр үрнәкләрне XVIII йөз әдәбиятыннан да таба алабыз: Кемнең дәгел, Алла, синең бу берлек, Мәдәд wир диим мән қайу йирлек

[ГМ. 68б], Соңын аңлаб төшмәдем һич хәwефә [ГМ. 45б], Нәк йаралдым, улсам икән туфрақ [ГМ. 68а], Гөнаһым күп дийү қанда китәргә / Wәғдәң бар: һәркемгә өмид итәргә [ГМ. 67б], Бу дөнйада үлмәйүбән, Кемнәр бақый қаласы [Гс. 41]; адәминең нәчә төрлүк қисме бар [УИ. 55]; Һәр ни дирсәм сүзимә қылма хилаф [УИ. 56]; Хуб белермән һәм үзем дип орма лаф [УИ. 56]; Һич нәмәне белмәгән йул йөрмәгән [УИ. 56]; Барча серрем сәңа мәғлүм, и Хода, Рәхмәтендин қылма безни сән җөда [XVIII гасыр тат. әд-ты, б. 95]; Қабул ит җөмлә хаҗәтен, Сәнеңдер бу қаму, әфлақ [XVIII гасыр тат. әд-ты, б. 95].

## 4.6. Фигыль

XVII–XVIII гасыр язма истәлекләре телендә фигыль сүз төркеменең тотрыклы грамматик категорияләр булуы ачыкланды. Наклонение, заман, зат-сан һәм барлык-юклык грамматик категорияләре күзәтелде.

Барлык-юклык категориясе фигыль формасы мәгънәсенә салынган эш-хәрәкәт, процессның булуын яки булмавын белдерә. Бу чор текстларында, шул исәптән, Мәүла Колый хикмәтләре һәм поэмаларында, эш кәгазьләрендә, XVIII йөз поэзиясе вәкилләре – Габди, Габдессәлам, Г. Мөслимов, Г. Утыз Имәни һ.б. әсәрләрендә – юклык мәгънәсе *-ма/-мә* аффикслары һәм аның вариантлары *-мый/-ми*й формалары ярдәмендә белдерелә: белмәдем ни дигәнен [МК. А65а.9]; Йоқлағанмыз уйанмый [МК. А68а.13]; чықмады ул [МК. А646.11]; малына қушмай [МК. Б726.8]; Бу дөнйада үлмәйүбән кемләр бақый қаласы [Гс. 42], Барырыңны белмәдем [Гс. 51]; Хақ зикерен димәдем һичбер аулақ [ГМ. 166]; дийә алмай белеп саныб берендин, инанма дошманә сән улма ғафил [УИ. 115].

### 4.6.1. Затланышлы фигыль формалары

Тикшерелә торган текстлар телендә хикәяләү, боеру, теләк һәм шарт наклонениеләре күзәтелә.

*Хикәя фигыль.* Хикәяләү наклонениесе реаль чынбарлыктагы эш-хәрәкәтне белдерә һәм заман категориясендә төрләнә. Поэмалар телендә үткән, хәзерге һәм киләчәк заманнар очрый.

Үткән заман хикәя фигыль Мәүла Колый хикмәтләре һәм поэмалары телендә *-ды/-де, -мыш/-меш* аффикслары ярдәмендә ясала. Әлеге формалар үткән заман мәгънәсен, ягъни сөйләм моментына кадәр

булган эш-хәрәкәтне белдерә. Билгеле үткән заман хикәя фигыль XVII–XVIII йөз истәлекләрендә түбәндәге кушымчаларны ала:

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | -ды-м/-дем,<br>-дум/-дүм | -дық/-дек,<br>-дуқ/-дүк |
| II зат | -ды-ң/-дең,<br>-дуң/-дүң | -дыңыз/-деңез |
| III зат | -ды/-де | -дылар/-деләр |

Мәүла Колый иҗатында кулланылышына мисаллар: қал+дум [МК. 3, 3, 3]; қыл+дум [МК. 30б]; +ды [МК. 15, 31б, 40]; +дым [МК. 30б]; +дың [МК. 18, 30б]; йат+дуң [МК. 30б]; +ды [МК. 25]; эшлә+дек [МК. 44].

*-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы үткән заман гомуми төрки форма булып санала һәм ул үткәндә булган билгеле эш-хәрәкәтне белдерә: Қул йаратдың тотмаға, бирдүң айақ йөрмәгә [МК. 25б]; Күрүб ғибрәт алмадық [МК. 35]; Хақ йаратды дөнйаға [МК. 35б]; Күңелдән кичермәдем ахирәт аһын [ГМ. 57а]; Китде бән ғәрибнең фиғеле азыб [ГМ. 47а]; Изге эшләр күренмәде күземә, ни эшләсәм, эшләдем үз үземә [ГМ. 47б]; Уфтанмай эшләдем, алдым ғасый [ГМ. 51а]; Ғәмәлемдә улмады бер саwаб [ГМ. 52а]; Хақ қоллығын бән қыла алмадым [ГМ. 61а].

Мисаллардан күренгәнчә, бу заман семантикасы буенча хәзерге татар әдәби телендәге кулланылышыннан аерылмый дип әйтергә мөмкин.

I зат берлектә һәм күплектә, II зат берлек санда *-ды/-де* кушымчасы иренләшкән вариантта да килә: *-дум/-дүм, -дук/-дүк, -дуң/-дүң*. Мәсәлән, күр+де [МК. 31б]; бир+де [МК. 16б]; йарат+ды [МК. 35б] һ.б.

III зат формаларының иренләшкән вариантта кулланылышы күзәтелмәде. Бу чор рәсми эш кәгазьләрендә, иренләшмәгән вариантка караганда, иренләшкән вариант чагыштырмача сирәгрәк очрый [Хисамова, 2006, б. 87]. Ф.М. Хисамова бу күренешне «традицион орфографиянең халык сөйләм теле тәэсирендә, яисә писарьларның грамоталылык дәрәҗәсенә бәйле рәвештә бозылуы» дип карый [Хисамова, 2006, б. 89]. Төрле аффиксларның иренләшкән һәм иренләшмәгән вариантта язылуы башка язма истәлекләрдә дә очрый һәм

тикшеренүчеләр биредә үзенә аерым эзлеклелек, закончалык булуын билгелиләр.

*-ды/-де, -ты/-те* кушымчаларының текстларда бирелешендә аерым үзенчәлекләр күзәтелә. Мәсәлән, саңгырау тартыкка тәмамланган сүзгә *-ты/-те* варианты түгел, яңгырау тартык белән булган формасы ялгана: йарат+ды [МК. 16б], кит+де [МК. 3, 4б, 17б, 31б], нийәт ит+де [МК. 3], үт+де [МК. 10, 30], ешлә+дек [МК. 44], һ.б.

Кушымча әсәрләрдә зат-сан аффикслары ярдәмендә төрләнә: Күб адәмне гүргә салды ошбу җиһан [МК. 1], Бернәчә сүз тәсғир хикмәт әйдең монда [МК. 1], Бернәчә көн йөрдең анда пәнһан улыб [МК. 30б], Эшләдек без күб хата [МК. 44], Аналар рөхменә төшдүң андин [МК. 30б], Қырық көн йатдуң анда хам қан булыб [МК. 30б]. Андин соңра тән булдуң дүрт ай тәмам [МК. 30б]; алды бидрәне гарәб итде тарәб, китде иве сарига гайре тәгьәб [УИ. 110].

I һәм II зат берлек сан кушымчалары алганда әлеге форма еш кына иренләшкән вариантта килә: сач + дуң [МК. 18], әйт + дүм [МК. 2б], бир + дүң [МК. 12, 18, 19, 25б] ;

*-ды/-де* кушымчалы үткән заманның юклык формасы фигыль нигезенә *-ма/-мә* аффиксы ялгану юлы белән ясала: Үлүм өчүн табмадылар һич даруны [МК. 131б]; Ирәнләр бу дөнйаны күзгә алмады, Дөнйа өчүн бер-беригә сүз димәде, Үләксәдәй дөнйа өчүн ғәм йиймәде [МК. 23].

Шул рәвешле, үткән заманның *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалары гомуми төрки форма булып санала һәм XVII–XVIII гасыр язма әдәби телендә актив кулланыла. Тикшерелә торган истәлекләрдә *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалары мәгънәләре буенча хәзерге татар әдәби теленнән аерылмый. Язылышта төрлелек бар, ягъни саңгырау тартыкка беткән нигезгә күпчелек очракларда яңгырау *-ды* кушылуы күзәтелә.

Нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль XVIII гасыр поэзиясендә *-ған/-гән* һәм *-мыш/-меш* кушымчалары белән ясала. М. Колый хикмәтләрендә *-ған/-гән* формасы норма булып тора: Хақ ғишқында ирәнләр ғашыйқдин хәлгә килгәнләр [МК. 38]; Йулларыны күндермешләр тәриқәткә [МК. 5б]; Нәфес йулын естәй йөреб йулдан азмыш [МК. 22]; Сәнең имди бу ғөмрең күпме қалған,/ Сәнең дәwүрендә нәчә ирләр үлгән. / Нәчә шаһлар, нәчә ағалар үлгән, – / Нәчә төрле хәкимләр йаңа улган. / Берәүнең атасы, анасы үлгән,/ Берәүнең күз нуры – баласы үлгән [УИ. 130]. Бу форма күбрәк III зат берлек һәм күплек формаларында кулланылган, сирәгрәк шулай ук I зат формалары

да очрый, I төр зат кушымчаларын ала; III зат берлектә һәм күплектә *-дыр/-дер, -дур/-дүр* аффиксы белән дә, аннан башка да килә .

*-мыш/-меш* кушымчасы нәтиҗәле үткән заман мәгънәсендә шулай ук еш кулланыла һәм III зат формасында гына килә: Рәхмәт бәхерен Хақ ташытмыш чумыб йатса [МК. 27]; Бостаның ачылмыш керә белсәм, илаһым [МК. 12]; Бу күңелне қабшамышдыр көфер-бидғәт, Күкерәкдә урнашмышдыр гөнаһ-золмәт [МК. 24]; Хәйлә берлә күндермешдер үз йулына / Хәлwәт эстәб, Алла сари қачмак йахшы [МК. 21б]; Нәфес берлә иш булғанлар дөнйа төзмеш / Хақ Тәғәлә әмренидин җөмлә бизмеш / Нәфес йулын эстәй йөреб / йулдан азмыш [МК. 21б]; Йаwлығым тулы йимеш, йарымдин хәбәр килмеш, Тормасын йитсен димеш [Гс. 51]; Дәһи бир безгә, ки без зар улмышмыз, Багә һәм гәлдин өлешсез қалмышмыз [XVIII гас тат. әд-ты. 90]; Чықармышлар шуның чөн нике нами [УИ. 85]; шур зәминдә улмыш аның мәскәни шураб ирмеш һәр заманда эчкәни / чуқ ирмеш дөнйада бу ширин шәраб күрмәмеш лик белмәмеш ул дил кәбаб [УИ. 110].

Нәтиҗәле үткән заман мәгънәсен белдерү өчен кайбер әсәрләрдә *-ыб/-еб, -уб/-үб* кушымчалы фигыльләр кулланылган: Нәчә йыллар үтебдер, йуқ йарар эш, ғөмеремне кичеребмен шуйлә буш [ГМ. 46а]; Нәчәләрнең меңдән узубдур ғөмре [ГМ. 44б]; улыбмыз бер беримезгә мөхалиф [УИ. 77]; күребмән бу җиһанда чуқ ғәваил [УИ. 78]; йимәк эчмәкнең улмыш мөбтәләсе/ улыбдыр нәфсе аның пишәwасе / бу рәсwалық белән қылыр дәғәwи/ қуйыбдыр иддиғадин исме һади [УИ. 78].

XVIII йөз поэзиясендә төрләнеш парадигмасы

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | -ыб /-уб/-мән | -ыб /-уб/ -без |
| II зат | -ыб /-уб/ -сән | -ыб /-уб/ -сыз,<br>-уб-сыз-лар |
| III зат | -ыб /-уб/ -дур | -ыб /-уб/ -лар |

Мисаллар: Белдүкемни сөйләйүбмән нәфғечөн шәйх-у-шәбаб [УИ. 30]. Эчең-тышың тулыбдыр дәғwә берлән [УИ. 82]; Эчебмез шунчә әнһаре wә күлдин [УИ. 84]; wиребләр тәртиби ул нөсхәләргә [УИ. 85]; Төшебдер ул китаблар ғәмиләргә [УИ. 85]; Имамның хақы диб йалған йазыблар / Нәфескә алданыб, йулдин азыблар [УИ. 88].

Мисаллардан ук күренгәнчә, бу форма кайбер авторларның, аерым алганда Габдерәхим Утыз Имәнинең, иҗатында мул кулланыла.

Күп кенә төрки язма истәлекләр өчен хас булган бу заман формасы XVIII йөз эш кәгазьләрендә дә очрый. Аны традицион әдәби тел тәэсире дип карыйлар, әмма бу очракта, Ф.М. Хисамова, киресенчә, шул чор татар теле сөйләшләренә хас диалекталь үзенчәлекләрнең әдәби телгә тәэсире дип карау дөресрәк булыр, ди [Хисамова, 1981, б. 90]. Чөнки традицион форма, мәсәлән, *-гучы/-гүче, -мақ/-мәк, -мақлық/-мәклек* формалары, башлыча, документларның башлам яки бетем өлгеләрендә яки рәсми стиль өчен хас тотрыклы сүзтезмәләрдә очрый һәм күпчелек документларда кабатлана. Ә *-ыб/-еб* кушымчалы заман бу очракта аерым бер төркем документлар өчен хас һәм документны яздыручы җитәкченең кайсы сөйләш вәкиле булуына бәйле булырга тиеш, һәм нигездә документларның төп эчтәлек өлешендә кулланыла. Тикшерелә торган документларда бу заман формасының II һәм III зат формалары теркәлгән.

Мәүла Колый хикмәтләрендә үткән заманның аналитик формалары гаять актив:

*-мыш иркән:* Рахман изем остаз қапуғын ачмыш иркән [МК. 3];

*-қан ирмеш:* Остазым Хақ йулына қайтқан ирмеш [МК. 3]; Мән ғәфилне дөнйа таба атқан ирмеш [МК. 3];

*-мыш ирде:* Остадым Хақ ғишқында тормыш ирде [МК. 3];

*-ыр иркән:* Хөллә кийеб нан wә ниғмәт йийәр иркән [МК. 23б].

Нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль XVIII гасыр поэзиясендә *-ган/-гән* кушымчалары белән ясала: Сәнең имди бу ғөмрең күпме қалған, / Сәнең дәүреңдә нәчә ирләр үлгән. / Нәчә шаһлар, нәчә ағалар үлгән, / Нәчә төрле хәкимләр йаңа улған. / Берәүнең атасы, анасы үлгән, / Берәүнең күз нуры – баласы үлгән [УИ. 130]; Борындин шаһға хезмәт әйләгәнләр ил эчендә әҗәлсез үлмәгәнләр [УИ. 122].

Кыпчак телләренә хас бу форма нигездә XVIII йөз шагыйрьләре телендә III зат берлек һәм күплектә кулланыла.

Рәсми эш кәгазьләренә килсәк, документларның характерына һәм алардагы сөйләм ситуациясенә бәйле рәвештә бу форма күбрәк III зат берлек һәм күплек формаларында кулланылган, сирәгрәк шулай ук I зат формалары да очрый, I төр зат кушымчаларын ала; III зат берлектә һәм күплектә *-дур/-дүр* аффиксы белән дә, аннан башка да килә [Хисамова, 1981, б. 94].

Нәтиҗәле үткән заман мәгънәсен белдерү өчен кайбер әсәрләрдә *-ыб/-еб, -уб/-үб* кушымчалы фигыльләр кулланылган.

Күптән үткән заман *-мыш ирде* формасы аша белдерелә. Мисаллар: Тотмыш ирде шур зәмин үзрә мәқәр [УИ. 108]; Табмыш ирде бу җиһанда чәй-қаймақыдин нәсиб [УИ. 51]. *-ган ирде* формасы очрамый.

Күптән үткән заманның *-мыш ирде* кушымчасы Г. Утыз Имәни иҗатында ешрак кулланыла, ә тәмамланмаган үткән заман *-а иде* формасы сирәк урын ала. Кабатлаулы үткән *-а торган иде* формасы шулай ук эш кәгазьләрендә генә очрый [Хисамова, 1981, б. 97], *-ачак иде* формасына мисаллар бөтенләй юк.

*Хәзерге заман хикәя фигыль -а/-ә* формалары ярдәмендә белдерелә һәм сөйләм моментында башкарылган эш-хәрәкәтне аңлата. Аларга зат аффикслары ялгана: Мисаллар: Қулың суныб алмайынча ағызқа килә, / Чәйнәмәйен излеб, үзе йотлур булғай [МК. 13б]; Бидғәт еше көндин көне төрләнәдер [МК. 22]; Йаз көнендә болыты аз – чуақ ула,/ Йегет кеше қайғусы йуқ даим көлә. / Қарый кеше мисле һәман қыш тик була [МК. 14б]; Йөзе гөлдин тәзадыр, /қашына қәләм йазадыр, / қашы күзе күмелсен, / күрсәм, күңлем азадыр [ГС. 46]; Рәхимеңә тотамын күз, йә рәфиғ [ГМ. 49б]; йөримез дөнйа қуып, арыб, ачыб [ГМ. 47а]; йөримен изге эшләрдән қачыб [ГМ. 47а]; Йаз көнендә болыты аз, чуақ ула [МК. 14б]; Йегет кеше қайғусы йуқ, даим көлә [МК. 14б].

Тикшерелгән чыганакларда хәзерге заман хикәя фигыль мәгънәсе *-ыр/-ер, -ар/-әр, -р* кушымчалары аша да белдерелә: Бу игенне ғәзиз белеб һәркем игәр [МК. 34]; Ихласлықлар төн-көн йығлаб, қылыр намаз, Иғтиқадлә Хақға қылыр рузә намаз, / Җөмлә эшен қабул қылыр ул бинийаз,/ Ихлассызның Хақ тиб сүзләр сүзе йуқдыр [МК. 7]; Шул сәбәбдин башың асманда йөрер [УИ. 55]. Әлеге кушымча Мәүла Колый иҗатында бу функциядә норма буларак билгеләнә. Ул хәзерге заманны, шул ук вакытта киләчәк заманны да белдерә. Хәзерге заман сөйләү моментында башкарылган эшнең дәвамлылыгын, кабатлануын белдерә: Нәфес тәнгә йийеб-эчеб / бирер қуәт [МК. 16]; эш гел кабатланып торуын, гадәткә керүен дә белдерә: Қыш килдисә, көнләре суық булур, Йақтысы аз, қараңғысы чуқ-чуқ булыр [МК. 14б].

Хәзерге заман шулай ук *-а торур* кушымчасы ярдәмендә ясала: Пирем заһир – батыйн ешен күрә торур [МК. 11]; *-ар ирде:* Ғишық утында көйенүбән бешәр ирде [МК. 7]; *-а ирде:* Тәүбә қылыб, Хақға йығлаб йәшләр сачсаң, тәмүғдин Хақ сәне йырақ қыла ирде [МК. 7б].

Хәзерге заман белән сорау биргәндә *-ар/-әр* кушымчасыннан соң *микән* сүзе кушыла: Бу күңлем мәхәббәтдин тулур микән [МК. 1б].

Хикмәтләрдә дәвамлы хәзерге заманны белдерү өчен *-ыб торур* формасы килә: Хызыр Илйас мәңгү суын ечеб торур [МК. 15б].

*Киләчәк заман хикәя фигыль.* Мәүла Колый әсәрләре телендә киләчәк заманның ике төрле формасын очратабыз: *-гай* формасы еш кулланыла һәм *-гай/-гәй, -кай/-кәй* һәм зат кушымчалары киләчәктә һичшиксез булачак, әмма сөйләүче яки башка бер затның теләгеннән торган эшне белдерә: Нәтәк җаwаб биргәймез [МК. 35]; Җан бағының миwәләре бешәр булғай [МК. 43б]; Фәрештәләр киткәйләр жаныны алыб [МК. 5], Қолак бирде әмрен күреб белгәймү диб [МК. 17]; Йир йөзендин бәрәкәтләр күтәрелгәй [МК. 7а]; Зәққумың шәрендин сақлагай идең, илаһым [МК. 12], Мәгәр бәнем өнемне ишетмәссез, / мәшғүл улыб доға да қылмағайсыз [ГМ. 68б] һ.б.

М. Колый иҗатында киләчәк заман шулай ук *-асы/-әсе* формасы аша белдерелә: Җөмлә қалмай үләсе [МК. 35]; Андин соңра мизаниға барасыдыр / Һәр ғәмәлең ул мизанға саласыдыр / Изге ғәмәл йиңсә чәндан буласыдыр / Йаwыз ғәмәл йиңәр булса бардыр хәтәр [МК. 42б]. Ул евүгә фәрештәләр киләседүр [МК. 29]; Андин соңра булгусидур мәхшәр көне [МК. 29б]. Аның иҗатында *-ур ирмеш* аналитик формасы да очрый: Йыйған малы монда хәрам қалур ирмеш [МК. 6б].

Юклык формасы тамырга *-мас* һәм аның фонетик варианты *-маз* кушымчасы ялгану нәтиҗәсендә ясала һәм соңгысы өстенлек итә: Чырағ йағыб һәргиз йанмаз йалан йирдә [МК. 10]; Бақисын сүзләмәгә йетмәз телем [МК. 14]; Қотылмас бу үлүмдин нәчә қачса [МК. 15]; Рәхим қылмаз үлүм нәчә йығлар ирсәң, Рибех алмас алтун-көмүш, гәүһәр бирсәң, Җиһан халкын йыйуб аңа җаwаб бирсәң, Һич кемсәнең сүзен тотмаз ушбу үлүм [МК. 15].

Бу формалар XVIII йөз истәлекләре телендә дә урын ала: күргәз [Гс. 68]; уйку килмәз [Гс. 69]; арзу қылмаз [Гс. 68–69], белмәз [Гс. 68–69], тормас [Гс. 69], улмас [Гс. 69].

Бу чор текстларында киләчәк заман хикәя фигыль *-ыр/-ер, -ар/ -әр, -р* аффикслары белән ясала һәм I төр зат кушымчалары белән төрләнә: Әйтдүм, дустлар, нәсыйхәт, бәндә сердәм сачарум [МК. 2]; Гөнаһларың кәчелер, / Уйаг тор қәдер төндә [МК. 12б]; Әмрүңә бойурурсән, қодрәт телең / Кем кәрәксә, тотар сән қодрәт қулың [МК. 20]; Ғәләм ечрә орыш, суғыш, бәла тулур [МК. 8].

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | -р-мән | -р-мыз, -р-мыз-лар |
| II зат | -р-сән, -р-син | -р-сыз, -р-сыз-лар |
| III зат | -р | -р-лар, -р-лар-дур |

Юклык аспекты *-мас* һәм *-маз* формаларында килә.

Мисаллар: Санамадым китәрем бер көн күчеп [ГМ. 46б]; Гәмәлсез ни қылырмын мән зәлил [ГМ. 55а]; Ни идәрем, ни қылырым, ни хәли [ГМ. 60а]; Китабларға әгәр қолақ салырсән, / Ходай тәүфиқ бирсен, кирәген алырсың [ГМ. 66б]; Мәгәр бәнем өнемне ишетмәссез,/ мәшғүл улыб доға да қылмағайсыз [ГМ. 68б].

Киләчәк заман хикәя фигыльнең XVIII гасыр эш кәгазьләрендә бер генә формасы теркәлгән. Ул *-ыр/-ер, -ар/-әр, -р* аффикслары белән ясала [Хисамова, 1981, б. 102]. XVIII йөз поэзиясендә бу кушымча киң кулланылыш ала. Ул зат кушымчалары белән дә төрләнә. Мисаллар: мәкр-ү-хәйлә дамени сезгә төзәр / тиз заманда шәһреңезни ул бозар [УИ.62]; Санамадым китәрем бер көн күчеп [ГМ. 46б]; Гәмәлсез ни қылырмын мән зәлил [ГМ. 55а]; Ни идәрем, ни қылырым, ни хәли [ГМ. 60а]; Китабларға әгәр қолақ салырсән, / Ходай тәүфиқ бирсен, кирәген алырсың [ГМ. 66б].

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | -р-мән | -р-ныз, -р-мыз-лар |
| II зат | -р-сән, -р-син | -р-сыз, -р-сыз-лар |
| III зат | -р | -р-лар, -р-лар-дур |

Юклык формасы *-мас/-мәс, -маз/-мәз* кушымчасы белән бирелә: Гәрибләрне һичбер адәм алмаз санға [МК. 23]; Мәгәр бәнем өнемне ишетмәссез, / мәшғүл улыб доға да қылмағайсыз [ГМ. 68б]; Гәрибләрне һичбер адәм алмаз санға, Аш йийәрсә, ләззәт бармаз һәргиз җанға, / Мәкянлылар миһманлашыр тиңле тиңгә, / ғәрибләри моң-зар булыб торыр иркән [МК. 23].

Киләчәк заман хикәя фигыльнең XVIII йөз әдипләре телендә *-ачак/-әчәк* формасы да күзәтелә: Ничә торсаң бу дөнйадан китәрсең, қуйылачақ йирә ахыр йитәрсең [ГМ. 42б]; Хақ эшене қылмыймын һич пөр ғәмдә, / Ахыры йитәчәк киләсе wәғдә [ГМ. 45а].

*-ысар* кушымчасы без караган текстларда очрамады.

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, бу чор әдәби телендә киләчәк заманның *-р* формасы норма булып тора.

*Боерык фигыль.* Мәүла Колый хикмәтләрендә боерык фигыльнең төрләнеш парадигмасы түбәндәгечә:

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| II зат | нуль форма, -ғыл /-гел<br>-ың/-ең | -ыңыз/-еңез,<br>-ыңыз-лар /<br>-еңез-ләр |
| III зат | -сун/-сүн,<br>-сын/-сен | -сун-лар/<br>-сүн-ләр |

Хәзерге татар әдәби телендә теләк фигыль *-ый/-и* кушымчалары белән ясала, ләкин аның I зат формасы гына бар һәм ул икенче төр зат кушымчалары ала [Татар грамматикасы 2002, б. 154].

Төрки һәм татар тел белемендә теләк фигыльне яки аерып, яки боерык фигыльгә кертеп карыйлар. Борынгы язма истәлекләрне тикшергән фәнни хезмәтләрдә дә теләк фигыль, башлыча, боерык фигыль белән бергә килә. Озак еллар буе татар теле тарихын өйрәнүгә зур көч куйган Л. Җәләй «Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар)» (Казан: Фикер, 2000) дигән хезмәтендә: «боерык фигыль, грамматик форма буларак, сөйләм практикабызда берничә семантик һәм стилистик төсмер чагылдыра; алар, башлыча, боерукушу (категорик императив), тыю (юклыкта), теләк, үтенеч, ялвару... мәгънәләреннән гыйбарәт», – ди [Җәләй, 2000, б. 176]. Автор беренче затка, ягъни сөйләүченең үз-үзенә боеруына карата әйтелгән фикерләрне тикшереп, бу төр фигыльне боерык-теләк дип атарга мөмкин дип саный [шунда ук].

XVI шагыйре Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» поэмасындагы фигыльне ныклап өйрәнгән Н. Борһанова да «семантика повелительного и желательного наклонений в языке исследуемого памятника четко не дифференцирована» дип билгели [Бурганова, 1980, с. 82].

*Теләк фигыль* М. Колый иҗатында I зат берлектә *-айын/-әйен, -айым/-әйем* кушымчасы белән белдерелә: Талашқанлар китәр, дөнйа қалыр, күргел / Ғибрәт алыб, тәүбә-тәүфиқ итәйен мән / Дөнйа өчен эт булмағыл, бизә күргел / Тәғәт өчүн җаным фида итәйен мән [МК. 21а].

Бу формалар, теләк белән бергә, боеруны да (үтенүне, рөхсәтне, ниятне һ.б.) белдерергә мөмкин.

М. Колый үзенең хикмәтләрендә бу форманы чагыштырмача сирәгрәк куллана: Килең, дуслар, бу үлемне йад итәлем / Белмәклеккә баш милкендә ғакыл булса [МК. 4б].

Борынгы язма ядкәрләрдә теләк мәгънәсен, теләк фигыль формаларыннан тыш, башка чаралар да белдерә ала. Һәр шагыйрь аларга еш мөрәҗәгать итә.

Боерык фигыльләр «җөмләнең төзелешенә һәм интонациясенә карап, күп төрле модаль мәгънәләр белдерә» [Татар грамматикасы 1999, б. 92]. Мәсәлән, *-сын/-сен, -сун/-сүн* формалары еш кына поэтик текстларда теләк мәгънәсе белән кулланылалар: Йөресүн Миср wә Шамда йарлығыңыз / Табуғда ырғасун күб йарлыларыңыз / Җиһан ханлары булсун колуңуз / Фәләккә йитсү хөкм ечрә колуңуз / Бу падишаһлыкда бәр хордар булуң / Өкүш йыл саг-сәламәт бар булуң [Котб].

Бу кушымчалар Аллаһка мөрәҗәгать иткәндә дә теләкне белдерә: Хақ бирмәсен һичбер кемгә ғәриблекне /ғәриблек барча хәлдә михнәт иркән [МК. 23]; Әймеш сүзем қабул қылсун рахман кәрим [МК. 3б].

М. Колый үзенең хикмәтләрендә теләкне белдерү өчен төрле чараларга мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, шарт фигыль формаларының көчле теләкне белдерү очраклары бар. Шарт фигыльнең *-са иде* формасы I зат берлек санда нәтиҗә өлешеннән башка килеп теләкне белдерә: Мән андин берин-берин татсам иде / Хаҗаҗ кеби рихләт қылу китсәм ирде, / Хаҗ ғөмере әрқәнларын табсам ирде / Тәwаф қылу морадыма йитсәм ирде [МК. 9]; Хақға тәғәт қылмақ фарыз сәңа, мәңа, / Тәғәт қылыб бу җиһандин үтсәм ирде [МК. 6].

М. Колый иҗатында *-ар ирдем* формасы да теләкне белдереп килгән очрак бар: Нәфсем минем туймас, дөнйа булса барии / Бу ғәләмне йотар ирдүм қомсыз булуб [МК. 31]. Бу форма хәзерге татар әдәби телендә дә кулланыла: Тәғәт-намаз қыла күр / Сәндин қалур бу дөнйа [МК. 31]; Хақ эшене ихлас илә тота күргел [МК. 27] кебек мисалларда шулай ук теләк мәгънәсе салынган.

Шарт фигыльнең *-са* кушымчасына *-чы* кисәкчәсе өстәлеп ясалган формасы шулай ук нәтиҗә өлешеннән башка килеп теләкне белдерә. Бу очракка да мисалны М. Колый иҗатында табарга була: Хаҗаҗ кеби йул сари йөрсәмче мән [МК. 9]; Ул бостанның йимешендин татсамчы мән [МК. 9]; Ихласилә Кәғба сари йөрсәмче мән [МК. 9]; Хаҗи булыб Хақ дидарын күрсәмче мән [МК. 9]; Барын салыб Кәғба сари китсәмче мән [МК. 9]; Ата-анадин даим алғыш алсамчы мән [МК. 9].

Мәүла Колый иҗатында хәзерге көндә мишәр диалекты һәм кайбер себер татарлары сөйләшләрендә кулланыла торган [Юсупов, 1986, с. 228] шактый үзенчәлекле *-гы/-ге + кәл-* формасы да урын алган. Әмма ул бары тик I зат берлектә генә кулланыла һәм күпчелек очракта *-гум кәлүр* фонетик вариантында килә, ә *-гым кәлүр* очрагы сирәгрәк: Мәхәббәт бостанының миwәсе чуқ / Миwәләрен ихлас илә татқум кәлүр [МК. 35]; Йөз йумаға ақның ағы – күздә йәшдүр / Йөзем ике күз йәшилә йуғум кәлүр [МК. 35]; Күкрәккә қара тулмыш, тыш сурәт ақ / Дәрд суилә күкрәгем йуғум кәлүр [МК. 35].

Шул битләрдә үк рәттән *бешкем килүр, сачкым киләр, кергүм килүр, йөргүм килүр* вариантлары да килә. Ул хәзерге көндә актив – *асы кил-* формасы вазифасын үти, ягъни авторның хәл итәргә теләгән эшен атый. Бу форма Шәмсетдин Зәки иҗатында да еш очрый: Ғәфләт уйқусындан уйғанғым килүр / Йарымы аңыб, аңа йанғым килүр [117]; Рәң, ширек, мәғсийәтдән арнуб/ Рәң тәүхид илә буйанғым килүр [117]; Суда йөзмеш каз илә үрдәк кеби / Мәғрифәт бәхрендә тулғанғым килүр [Юсупов, 2006, с. 102]

Кайбер очракларда М. Колый хикмәтләрендә *-гу* формасы, *ди-* фигыле белән янәшә килеп, кыек сөйләмне формалаштыра: Зина қылғум тийү һәркем күңелгә алса; / Сират күпрен сағ-сәләмәт кәчкүм дисәң,/ Ихлас илә тәүбә-тәүфиқ қыла күргел; / Күргел, коңыз йорт иткем тиб тизәк тотар, / Суық булса, кара йиргә инеб китәр [МК. 6б].

Әхмәт Ясәви хикмәтләрендә *-гы* үзе генә килеп тә теләкне белдерә: Хакыйкат лек чын гашыйкка төхфә биргем / Рузы мәхшәр нәчек сән дип хәлен соргым [Ясәви 55].

Теләк мәгънәсе Мәүла Колый әсәрләрендә сирәк кенә *-мага тели-* формасы белән дә белдерелә: Закирларның һиммәтен / Теләрем мән күрмәгә [МК. 32б]; Иблис ләғин булубдур әнғәбини бел, / Аны йимеш булсаң, йығла, тәүбәләр қыл [МК. 14].

*Боерык фигыль.* Әсәрләрнең характерына бәйле рәвештә аларда боерык фигыль формалары аеруча күп кулланылган. Боеру мәгънәсен белдерү өчен, хәзерге әдәби телдәге кебек үк, боеру наклонениесе фигыльләре килә, һәм традицион формалардан икенче затка боеру өчен *-гай/-гәй, -ма/-мә* кушымчалы фигыльләр зур урын алып тора.

II, III затларда теркәлгән һәм төрләнеш парадигмасы түбәндәгечә:

Габди шигырьләре тулысынча боеру, сорау, үтенүне белдерү формаларына нигезләнеп төзелгән. Мисаллар: Сәлам бирсә, галәйкә алма, / Сүзләренә бер дәм орма, / Мәсҗидтә бергә булсаң, / Қатларында, кит,

ултырма [Габди. 15]; Биргәнегә шөкер кылыб / Һәр ни булса, бергә йийгеңез./ Бу дөнйада тәғәт қылыб, / Оҗмахда хөллә кийеңез [Габди. 16];

III зат боерык фигыль шулай ук теләкне белдерү өчен дә кулланыла: Ғийал туғса шундағ туғсын, / Дин эшендә әда қылсын, / Дөнйа эшен тәрек қылып, / Ахирәткә убалансын./ Тәғәт қылыб, тәүбә берлә Чымырғанып чобалансын, Мондағ булмый ғийал туғса, Борыны һәм томалансын [Габди.16].

Юклыкта: Бинамазлар хәстә булса, хәлен сорма, алма күзгә [Габди. 13];

Күплектә: Биш намазны қылыңыз, үлем хәзер килгүче [Гс.50]; Йахшыларға улыңыз йахшы, / йаманға улмасын күзеңез wәхши [ГМ. 66б].

II зат боерык фигыльнең *-ғыл/-гел* (берлектә) һәм *-ың/-ең* (күплектә) формалары XVIII йөз шагыйрьләре иҗатында актив. Мәсәлән, Габди, Хәмид Йосыф углы, Г. Мөслимов шигырьләреннән мисаллар китерә алабыз: Қөдрәтиң бар йарлықасаң барчани, / Рәхим иткел барчаларға сән ғәни. /Ахыр дәмдә ғата иман әйләгел. / Ул дузахдин безни аман әйләгел. / Ул тәмүғдин безни азад әйләгел, / Рәхмәтең дидарә ғәрқ әйләгел. / Безләри сән үзиңә қол әйләгел, / Мостафаға безни өммәт әйләгел. / Ул дузахдин безләри дәwер әйләгел, / Җәннәт эчрә эшемез хур әйләгел. / Ул тәмүғни безә хәрам әйләгел, / Дидариңни безә хәлал әйләгел [XVIII гас. тат. әд-ты, б. 95], мөселманлар сабыр қылыңыз, ағыр булды бу дәwер [Габди. 16].

Аналитик формалардан теләк мәгънәсендә *-са иде (ирде)* формасы аеруча актив, һәм бу чор шагыйрьләре иҗатында аның төрле зат формалары теркәлгән: Сәнең күркәм җәмалыңны йакындин күрсәм иде; Алла йәрдәм бирүбән, һай, қуйныма алсам иде [Гс. 59].

Теләк модальлеген белдерү өчен бу чор әсәрләрендә һәм теләк наклонениесе, һәм теләкне белдерүче аналитик формалар кулланылган.

*Шарт фигыль.* Шарт наклонениесе икенче бер эшнең үтәлүе өчен кирәкле шарт мәгънәсен белдерә һәм гомуми торки формасы *-са/-сә* аффикслары ярдәмендә ясала. Мисаллар: Ғәфләтеңдин күзем айрыб, ғәмәл тезсәм, Дәһер ғәмин йийиәклекдин җөмлә бизсәм, Нәфес сөйгән эшләрдин бән күңел орсам, Дөнйа-ахирәт эшләр мәңа асан улыр [МК. 21]; Нә қылсамыз алға төшер [МК. 21]; Сыйратдин кәчсәң әман Дидар күргәзгәй хәнан [МК. 26]; Кем тот-

са анының сөннәтен, Аңар қылур шәфкәтен [МК. 26б]; Тәғәтдә ушбу көн ихласымыз бағласақ, Золмәтле тәмуғың күрмәз ирдек, илаһым [МК. 12] .

*-ган булса, -а торган булса, -ыр/-мас (-маз) булса, -асы булса:* Тереклекдә рузә-тәғәт қылған булсаң, Үлеб барсаң гүр өйендә рәхәт булыр [МК. 38б]; Қыш килдисә, көнләр суық булур [МК. 14б]; Һәр уғыл қыз ата ананы белүр булса, ғиззәт, хөрмәт берлә хезмәт қылур ирсә, Ул уғыл қыз Хақ дустыдыр белмәк кәрәк [МК. 4б]; Китәр исәм бу җан көзе рәушан улур [МК. 21]; Кем нәфсене йиңде ирсә – ирнең ире, Қийәмәт көн булур анын җәннәт йире [МК. 22].

Бу дөнйадин иман берлә үтәр булса,
Гүрдә йулдаш гүр эчерә йатар имеш,
Оҗмахқа илтәр қийамәт көн йетәр булса
Оҗмах өмид идеб иман айғум кәлер [МК. 5б].

Шарт фигыль *иде* ярдәмче фигыле, *икән*, *-чы/-че* кисәкчәләре белән килеп, теләк, үкенү, шелтәләү кебек модаль мәгънәләр белдерүгә Мәүла Колый хикмәтләрендә мисалларны күпләп табып була. 11 нче хикмәт тулысы белән түбәндәге рәвештә төзелгән, һәм анда бу очракка 10 мисал теркәлгән: Ул бостанның йимешендин татсамчы мән [МК. 9]; Суфилык миwәләре пешеб йитмеш, / Мән андин берин берин татысам иде, / Ул миwәнең ләззәтендин мәст улубән, Үздин китеб, иссез булыб йатсам ирде [МК. 7]; Тәғәт бәхре ақды чықды, ақыб бара, Бу күңлем кубнәси илә буғсам ирде [МК. 5б]; Намаз рәүшан нуры торыр ушбу йөзнең / Намаз қылыб, йөзем рәүшан қылсам ирде [МК. 6]; Мөэмин ирсәң рузә-намаз булсын эшең Хақ ғишкилә тулсын сәнең эчен-тышың [МК. 22б].

Шарт наклонениесе XVII–XVIII гасыр поэзиясендә башка әдипләр телендә дә *-са/-сә* кушымчалары аша бирелә: Доғам қабул булса, Хақдин ғынадыр. 69а]; Инанмасаң қара, Қоръәндә йазылмышын [ГМ. 67а]; Һәркемнең улырса диле қаты, Телендә аз булыр Алла аты [ГМ. 66б]; Улмаса мәдәд, миндә ни дәрман [ГМ. 64б]; Қар йағмур йағса, йәшәрмидер таш [ГМ. 46а]; Ничә дорсақ бу дөнйада, улым wафа, Эшем ахирәттә безгә җәфа [ГМ.45б]; Нәсыйхәттә һәр кемнең улса күңеле wар, қараса, китаблардан күб табар [ГМ. 45б].

Бу чор текстларында шарт наклонениесенең *-ды исә, -ыр булса, -дисә, -ур ирсә/-үр ирсә, -ур булса, -ды ирсә* кебек аналитик формалары актив түгел.

Шулай итеп, текстларда шарт наклонениесенең төп күрсәткече булып *-са/-сә* формасы тора. Шарт мәгънәсе шулай ук аналитик формалар белән дә белдерелергә мөмкин.

### 4.6.2. Затланышсыз фигыль формалары

*Сыйфат фигыль.* Сыйфат фигыль – үзендә фигыль һәм сыйфат сүз төркеменә хас үзенчәлекләрне берләштергән затланышсыз фигыль. Текстларда: Ғәмәл тартар тәразу бар, белгел аны, / Килен кебек бизәнеб алдағучы бу дөнйа [МК. 29б]; Тотар қуллар, гизәр айақ хәлсез қалғай [МК. 33]; Қылмыш эшләр Хақ мизәндә тартылғусы [МК. 33б]; Үләр булса, казгандыгы улыр фәна [МК. 33б]; Шәкердләр тулыб торған айға йаңлиғ [МК. 34]; Үлмешени анда белүр, сорар булсаң [МК. 27б].

*-ған/-гән, -қан/-кән* кушымчалы сыйфат фигыль XVII–XVIII гасыр язма текстларында сыйфат фигыльнең иң актив формасы булып тора: Хәләлмедер, хәрәммедер йигән ашым [ГМ. 45а]; Бу китабта бойорылған әмери / бойрылмаған эшләреңдән қал бире [ГМ. 44б]; Йөзе тулған ай кебек [Гс. 31а]; Туң күз ирде һич нәмәни белмәгән / йахшы дустларның сүзигә кермәгән [УИ(ТГ). 31].

Г. Утыз Имәнинең 24 юллык «Мәрсиян Габденнасыйр вәләде Габдерәхим» шигырендә 18 урында әлеге кушымча килә: Кичәләрне йите бүлгән / мәнем өчен уйаған торған / кечеклекдә сөтен биргән / шәфиқамдин җөда булдым [УИ. 31].

*-ған/-гән* формасы аергыч функциясендә килеп, башкарыла торган эш-хәрәкәтнең субъектын, объектын, урынын һам вакытын күрсәтә.

Әлеге форма, исемләшеп, тартым белән төрләнә һәм баш, юнәлеш, урын-вакыт килешләрендә килә.

Башка төрки телләрне тикшерүчеләр күрсәткәнчә, исемләшкән сыйфат фигыльләр, гадәттә, баш килеш формасында кулланылалар һәм гомуми эш башкаручыны белдерәләр.

Билгеле булганча, *-ған/-гән* формасы төрки телләрнең кыпчак төркеменә хас күрсәткеч санала. Бу чор истәлекләре телендә, үткән заман сыйфат фигыль мәгънәсен белдергәндә, әлеге форманың угыз варианты *-ан/-ән* аффиксы да актив кулланыла.

*-ан/-ән* формалы сыйфат фигыль. Тартык авазга тәмамланган нигезләргә *-ан/-ән* ялгана: Сүзнең қәдрен белән, сүзгә әһел зат / Алыр бу сүзләремдин тәғм wә ләззәт [УИ. 104], сузыкка тәмамланган нигезләр *-йан/-йән* аффиксын ала.

Бу форма сыйфат фигыль юклык формасы *-маған/-мәгән, -майан/-мәйән* аффикслары белән ясала: Ихлас илә эстәмәгән йарны булмаз [МК. 24б]; Тәхәммел әйләмәйән җәүрү көлфәт [УИ. 74]; Алладин ниғмәт бер диб белмәгәнгә, Хақны бер тиб, туғры йулға кермәгәнгә, Мал ниғмәт шөкранәсени қылмағанға, Зарлық илә һич хайерсез михнәте бар [МК. 28б].

Әлеге формалы сыйфат фигыль аергыч функциясендә дә кулланыла ала һәм исемләшергә дә мөмкин: Төнлә уйағ торғанлар / Сәхәрдә зад қылғанлар / Утдин азад булғанлар / Булса уйағ сәхәрдә [МК. 13]; Нәфес берлә иш булғанлар дөнйа төзмеш [МК. 21б]. Гадәттә исемләшкән сыйфат фигыльләр, эш-хәлнең субъектын белдереп, баш килеш формасында киләләр.

*-дық/-дек* формалы сыйфат фигыль борынгы төрки форма булып санала һәм хәзерге төрки телләрнең угыз төркеменә хас: Тордықы йирендә қалды ул һаман [УИ. 105]; Ғәделләрдер ходаның сәүдеке кол [УИ. 127] .

XVIII йөз әсәрләре телендә әлеге форма атрибутив мәгънәдә еш очрамый, исемләшкән вакытта тартым аффиксларын ала һәм баш, төшем, чыгыш, урын-вакыт килешләрендә кулланыла: Эчдеке һәм йийдеке шураб иде [УИ.108].

*-мыш/-меш* формалы сыйфат фигыль дә угыз телләре күрсәткече булып санала. Бу формалы сыйфат фигыль аергыч функциясендә килеп, предмет, затның билгесен үткән заман төсмере белән белдерә: Йар төзмеш бостан бардыр, аты җәннәт, Ул бостанда бирер микән урын мәңа [МК. 24б]; Исмәғил Хақ әмеринә буйын сонды, / Буғазланмыш хәлдә дидар күрмешдүр ул [МК. 24б].

Үткән заман сыйфат фигыль формалары булып, *-ған/-гән, -ан/-ән, -мыш/-меш* аффикслары килә, әмма аларның кулланылу ешлыгы төрлечә. Иң актив форма – ул *-ған/-гән* кушымчасы һәм ул бу чорда норма булып тора: wафат улған йирем бәнем – Таифә-и урыс арасы [Гс. 42]; Байның қызы бай кебек, Йөзе тулған ай кебек, Күз өстендә қашлары, қорыб қуйған йәй кебек [Гс. 45];

Бу форма, еш кына, исемләшә һәм килеш, тартым белән төрләнә. Мисаллар: Төнлә-төнлә йөргәнгә төн саwабы бир, Ходай. Аны күреб сөйләгәнгә Җан талақы бер Ходай [Гс. 47]; Биргәнегә шөкер қылыб, һәр ни булса, бергә йийгеңез [Габди. 17]; Нәфсе шомға ойығанлар Дузәх эчрә алынадыр [Габди. 17]; уқығанни тыңлайанни йазанни рәхмәтеңдә йарлықағыл йа ғәни [УИ. 70].

*-дык* кушымчасы атрибутив функциядә күзәтелми, әмма исемләшеп кулланыла. Казгандыгың җөмлә мал мирас улыб калгучы [Гс. 49] мисалында *-дык* формасы исемләшкән. Эчдеке һәм йийдеке шураб иде [УИ. 108]; Ғашиқ улан кемсәнәләр йөрер аның йулындин [Гс. 59].

Хәзерге заман сыйфат фигыльнең синтетик төре ике вариантта килә: беренчедән, ул борынгы уйгыр теленнән үк килә торган *-гучы* аффиксы белән белдерелә, икенчедән, шул ук аффикс халык сөйләм теле тәэсирендә хәзерге телдәгечә *-учы/-үче* вариантында да кулланыла. Бу ике форманың кулланылыш ешлыгы бердәй дияргә мөмкин. Габдессәлам иҗатында актив. Мәсәлән, Илаһи бәет әлеге формалар рифмасыннан җыела: Тәқдир әҗәл килүче / Татлиғ җаның алғучы / қоруғ гәүдә қалубән җаның җөдә булғучы / Wафа қылдық бер айлар / wәйран улыб қалғучы / қазғандығың җөмлә мал / Мирас улыб қалғучы / Зары қылыб қалғучы / Дөнйа тунын алғучы / Кәфен тунын сарғучы / Гүргә илтеб қуйубән қараңғыға қалғучы [Гс. 49];

Ф.М. Хисамова хезмәтләреннән күренгәнчә, ул рәсми документларда да шулай: Кунғур қәлға тарафында йатқучы пулкавай ыстаршина Батырқай Иткенә уғлы... (19 б.); Сән Салу авылында торғучы ыстаршина Шәриф Йақуб уғлына рипурт. (245 б.). Документларның башлам өлгеләрендә хәбәрлек кушымчасы алып, хәбәр функциясендә килү очраклары да бар: Питр Фидрич үзе тотқучыдыр... (149 б.) [Хисамова, 1981, б. 86].

Икенче бер традицион форма *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыль без караган әсәрләрдә кулланылыш тапмаган. Бу форма шулай ук рәсми эш кәгазьләренең башлам өлешләрендә һәм тотрыклы сүзтезмәләрдә теркәлгән. *-дық/-дек, -дуқ/-дүк* формасының кулланылышы да аерым мисаллар белән чикләнә. Документларда атрибутив позициядәге *-мыш* формасы барлыгы 24 мәртәбә кабатлана, һәм 14 очракта ул бер үк фигыль нигезенә ялгана һәм түбәндәге типтагы сүзтезмәләр барлыкка китерә: ‘йибәрелмеш пулкувник’, ‘йибәрелмеш ғәскәр башлыгы’, ‘рипурт илән йибәрелмеш кеше’, ‘йибәрелмеш йазу’ һ.б. [Хисамова, 1981, б. 87].

*-ыр/-ер, -ар/-әр, -р* кушымчалы сыйфат фигыль XVIII йөз текстларында атрибутив позициядә килә: Тағәт қылмай нә йатырсыз, Тар қәбердер йатыр йиреңез [Габди. 16].

*-ыр* формасының исемләшүенә дә мисаллар бар: Барырыңны белмәдем, барыб йулда тормадым [Гс. 51];

*-асы* кушымчалы фигыль документларда, хәзерге татар теле диалектларындагы кебек үк, хәбәр функциясендә теркәлгән: Артымызда йүнләр кешемез буласы дәгүл... [154 б.].

Бу чорның без караган язма истәлекләрендә сыйфат фигыльнең *-ачак/-әчәк* формаларына мисал табылмады.

Шулай итеп, XVIII гасыр әдипләре әсәрләре телендә сыйфат фигыльләрнең кулланылышы нигездә хәзерге әдәби телгә бик якын.

*Хәл фигыльләр. -ыб/-еб* формалы хәл фигыль М. Колый, Габди, Г. Мөслими, Г. Тайсугани, Г. Утыз Имәни әсәрләре телендә еш кулланыла һәм түбәндәге мәгънә төсмерләрен белдерә:

а) төп эштән алда булган эш-хәрәкәтне: Бимәкән wә бичара ғөрбәт чигеб, йөрәкендә хәсрәт уты йанар иркән [МК. 23], Җандин җөда булыб бу тән гүргә күчәр / Гүр эчерә терек булыб күзен ачар [МК. 1];

ә) төп фигыль белән бер үк вакытта, параллель булган эш-хәлне: Сәрлек булыб гөнчәләнүр җөмлә бисәр [МК. 43], Һәркем сиңа сығыныб өмид итәр [ГМ. 68 а]; Йаwыз йулдин қайтарыб, wиргел тәүфиқ [ГМ. 68а], Йаwыз эшне қуйыб, хақ йулға кит [ГМ. 66б];

б) бер-бер артлы башкарылган һәм бер мәгънә белән берләштерелгән мөстәкыйль эш-хәрәкәтне: Җөмлә тәнең ғәләбә қылыб қортлар йийде [МК. 25]; Хәйлә илә тотыб аны нагяһан, Ул ләғинә wирделәр һәм чикде михнәт ул аwан [XVIII гасыр тат. әд-ты, б.169].

Хәл фигыльнең *-убән* формасы Мәүла Колый иҗатында урын ала. Хикмәтләрдә 16 урында кулланыла: Ул миwәнең ләззәтендин мәст улубән / Үздин китеб, иссез булыб йатсам ирде [МК. 7]; Суфилықда тәүфиқ табса иркәк-теше / ғишық утында көйенүбән пешәр ирде [МК. 7]; Арқан-арқан атланубән башқа чықа [МК. 40б]; сәңа күз тотубән, күстәрер йул [МК. 39]; ғишық утын қабызубән, йақсам чырағ [МК. 35]; җан бушанубән тәндин чықар [МК. 27б].

Бу хикмәтләрдә М.Колый алдагы бәетләрне *-ыб* формалы хәл фигыль белән төзесә, соңгысында, шигырь юлларының ритмикасы таләбе белән, *-убән* вариантына мөрәҗәгать итә: Хәйwан-хәшәрәт туғыб/ Йумуртқадин қош чығыб / Җөмлә җанлиғ кол булыб/ Сәңа әйтүр, солтаным / Йирдин нәбат туғубән / Гөнчәдән гөл чығубән / Былбыл қошлар сайрабән / Зикрүң әйтүр, солтаным [МК. 19].

Хәл фигыльләрдән XVIII йөз язма истәлекләрендә дә иң актив кулланылган форма – *-б, -ыб/-еб, -уб/-үб* кушымчалы фигыль. Ул төп фигыльдән алда булган һәм төп фигыль белән бер ук вакытта булган эш-хәлләрне белдерә: Көттермәйен күтәреб ор, башы тисен қатқан

ташқа [Габди. 14]; Рузә тотыб, намаз қылғыл, бу дөнйада бетер эше [Габди. 15]; Сират күперен кичереб, оҗмахға да илтүче [Гс. 5014]; Қолақ дотыб бер сүземне дыңлаңыз [ГМ. 44а]; Йөримен изге эшләрдән қачыб, изге сүзне сүзләмәдем тел ачыб, Йөрүргә теләй күңел, бәлки, очыб, хисабламай йатырыны йир қочыб [ГМ. 46б].

Сузыктан соң *-йуб/-йүб* формасында кулланылган: Нәләр йийүб төне көне әйләдем нуш [ГМ. 46а].

*-ыб/-еб* һәм *-а/-ә* кушымчалы хәл фигыльләрнең юклык аспекты *-май/-мәй, -майынча/-мәйенчә* формалары белән белдерелә: Биренмәй агарды сач, сакал, баш [ГМ.46б]; Нәсыйхәткә кермәйен, йөримез тыш [ГМ. 46а]; Нәчәләр бу дөнйаны дотдылар, нийәтенә йитмичә үлделәр [ГМ. 46а]; Бер гөнаһ кылдым, тынмайын озак [ГМ. 54а].

*-убән* формалы хәл фигыль XVII–XVIII гасыр әдипләр әсәрләрендә *-ыб/-еб* күрсәткечле хәл фигыльнең грамматик синонимы булып тора һәм төп эштән алда булган процессны, төп эш белән бер үк вакытта яки параллель башкарылган эш-хәрәкәтне, төп эшнең үтәлү рәвешен белдерә: Бу ғәзиз җан бушанубән тәндин чықар [МК 27б]; Ғибрәт күреб, wасый дирүб ғақылә килсәң [МК. 40]; Қызыл йөзләр сарғайубән қаны беткәй [МК. 33];

*-ыб/-еб* формасы функциясен *-у/-ү* кушымчасы да үти: Шәрғы сөннәт эстәйү монда килән [УИ.55]; Гөнаһым күб дийү қанда китәргә [ГМ. 67б].

XVII–XVIII йөз поэзиясе телендә *-а/-ә* кушымчалы хәл фигыль кабатланып килгән очракларга да мисаллар шактый очрады: ғәфләт берлә йоқлай йоқлай ғөмре үтсә [МК. 27б]; Нәҗес дөнйа қуа қуа арыдум мән [МК. 24]; Тәwаф илә күчә-күчә Хозыр Илйас иртә кәчә, догалары кабул улсын, хуш гүзәл Болгар йулында [XVIII гасыр тат. әд-ты, б. 123]; Эстәй эстәй кәтде илдин та озағ [УИ.108]. XVIII йөз эш кәгазьләрендә бары тик бер мисалда гына шулай ук угыз телләренә хас булганча сузык аваздан соң *-йә* вариантында кулланылган: Хақ тәғәлә сезгә йәрдәмне өстәйә бирсүн... (180 б.) [Хисамова, 1981, б. 89].

*-ғач/-гәч* кушымчалы хәл фигыльгә бу чор әдипләренең шигырь текстларында мисал табылмады. Аның функциясен, нигездә, *-ды исә* формасы үти, ул XVIII йөз эш кәгазьләрендә урын ала: Безләр килеп әрмийә җыйа башлағач хуш күрделәр... (178 б., арт.) [Хисамова, 1981, б. 89].

Хәл фигыльнең *-ғанчы/-гәнче* формасы поэзия телендә очрамый, бары тик эш кәгазьләрендә генә күренә, әмма актив түгел: Ул урус-

лар килгәнче Котлы килделәр ул Йамансарыны тотқанлар... (25 б.) [Хисамова, 1981, б. 89]. Таур бетмәдин һәр кемнең йулы үтәр [ГМ. 68б] мисалында -*мәдин* кушымчасы шул функциядә килә. Таур бетми, йаwыз эшкә wарманңыз [ГМ. 70а] җөмләсендә -*ми* кушымчасы да шул ук очракка мисал була ала.

Г. Утыз Имәни иҗатында да хәл фигыльнең югарыда искә алынган барлык формалары урын ала: һәр кешинең сүзигә йөрмә кереб, дин вә дөнйаңны аңа әлдин виреб [УИ. 56]; Гәрчә сән күб белдең ирсә сорагыл, сормайынча бер қәдәм йул йөрмәгел [УИ. 56]; туғры йулдин сорашубән йөрдиләр [УИ. 56]; тук улыб анда түшәккә йатасән [УИ. 65]; миһман идеб һәрбери еwгә әйтәр [УИ. 65].

XVIII гасыр поэзиясе телендә хәл фигыль мәгънәсен белдерү өчен -*ыб*/-*еб, -убән* һ.б. формалары кулланыла, алар үзләренең кулланылыш үзенчәлекләре һәм мәгънә төсмерләре белән хәзерге татар әдәби теленнән нык аерылмыйлар.

*Исем фигыльләр*. Исем фигыль – үзендә фигыль һәм исем үзенчәлекләрен берләштергән фигыль формасы.

XVII–XVIII йөз поэзиясендә -*мак*/-*мәк* формасы – исем фигыльнең иң актив кушымчасы. М. Колый, Габди, Габдессәлам, Габделмәннан Мөслимов һәм башка шагыйрьләр телендә ул еш очрый. Исем фигыльнең -*мақ*/-*мәк* формасы М. Колый хикмәтләрендә төрле бәйлек һәм бәйлек сүзләр белән актив кулланыла. Мәсәлән, җыентыкның 32 нче бүлегендәге 13 дүртьюллыкта исем фигыль + *өчен* бәйлеге конструкциясе 15 урында килә:

Сәҗдә өчүн бирде Алла ике тези, сәҗдә йирин күрмәк өчүн ике күзи. Сәҗдәгә орғыл: маңлай, ике йөзени, Ике айақ, тез Хақға сәҗдә қылмақ өчүн [МК. 16б]; Оҗмах йулын табмақ өчүн уқы ғилем [МК. 14]; Сыйрат күпрен күчмәк көнгә ике қанат [МК. 6]. Бу мисалларда исем фигыль, *өчен* бәйлеге белән килеп, эш-хәлнең үтәлү максатын белдерә.

Ия функциясендә килә: Үз дидарын күрмәкне Хақ рузи қылсын [МК. 8б]; Хәләл берлә сөйешмәке татлиғ балдин [МК. 24]; Рәхмәтеңдин Хақның өмид өзмәк йуқдыр [МК. 24].

Аергыч функциясендә килә: Суфилықга йетмәк кеше әләм ирмәз [МК. 7б].

-*мақ*/-*мәк* формасы *торур* ярдәмче фигыле белән килгәндә исем хәбәр функциясендә килә: Ата ананы уғыл-кыз сүксә, белең, / Шәриғатдә кисмәк торур моның телен, / Қулы берлә суғар булса, йәнә қулын / Буынындин кисмәк торыр, белмәк кәрәк [МК. 4б].

Күпчелек очракта *-мақ/-мәк* формасы исемләшә һәм тартым, килеш белән төрләнә. Әлеге форма баш, иялек, төшем, урын-вакыт килешләрендә кулланыла: йийммәккә нан табалмай қарным ачды [УИ.78].

*-мақ/-мәк* формалы исем фигыльдән *-лық* аффиксы ярдәмендә ясалган исемнәр хикмәтләрдә очрый: коткармаклык [МК. 20б], кәчүрмәклек [МК. 21]; Хәмед қылыб Хақ йадыны айтмақлыққа, / Бу телем фәсыйхлыкка килер микән? / Хақ рәсүле сөннәтләрен тотмақлыққа, / Бу күңлем мәхәббәтдин тулырмикән [МК. 1]. Бу чор поэзиясендә *-мақ+кәрәк* конструкциясе актив: Монлар қылған доға сиңа булмаз тимәң, / Бу хәтәрдин хәсрәт йотыб тормақ кәрәк [МК. 4б]; Ата-ана тугырды безне, мөхиб дуслар, / Хөрмәтләрен йахшы қылыб йөрмәк кәрәк;/ Аһ waһ тийү күңелләре мөшкел булса, / Хәлләрене тәғзим берлә сормақ кәрәк [МК. 4б].

*-у/-ү* формалы исем фигыль хәзерге татар әдәби теле һәм аның диалектларында төп форма булып саналса да, XVII–XVIII гасыр истәлекләре телендә аның кулланылышы чикләнгән, әмма Г. Утыз Имәни иҗатында ул шактый еш кулланыла: Аны орышу нигүләрдин ғөрефдер [УИ. 133]. *-у/-ү* формасы еш кына исемләшә һәм килеше кушымчалары белән килә: көтәһ кисеб йинел үлчәб сатудин / сакыйн жанын җәһәннәмгә атудин [УИ. 127]; әгәр надан қалырса ул уқудин булыр ата ана ғасый бу турыдин [УИ. 133]. Г. Утыз Имәнинең «Мөһиммәт-еззаман» поэмасында бүлек исемнәре, еш кына, исем фигыльнең *-мак* кушымчасы белән формалаша: «Сату итмәк бәйаны», «Гомер итмәкнең бәйаны», «Үгет әйләмәк бәйаны» һ.б.

Бу чор рәсми эш кәгазьләрендә исем фигыльнең кулланылышында да шул ук закончалык күзәтелә: традицион *-мак/-мәк* формасы нигездә документларның бетем өлгеләрендә һәм тотрыклы сүзтезмәләрдә килә, калган очракларда *-у/-ү* формасы урын ала [Хисамова, 1981. б. 89].

Исем фигыльләрдән бу чорда, нигездә, ике форма актив кулланылышка ия. Аларның беренчесе – шул чор халык сөйләм телендә кулланылган һәм икенчесе – асылда кыпчак телләре өчен хас булган *-у/-ү* формасы һәм традицион әдәби телләрдән үк килә торган *-мақ/-мәк, -мақлық/-мәклек* формалары, һәм алар норма вариантлылыгын бирәләр.

Габдессәлам иҗатында исем фигыльнең *-ыш* формасы кулланыла: ғәҗәб сәнең налишың, Буйыңа қул салышың, Хәрир зибаға охшар һәрбер айақ басышың [Гс. 50]. Ул, хәзерге татар телендәге ке-

бек үк, тартым һәм килеш кушымчалары белән һәм бәйлекләр белән кулланыла:

*Инфинитив.* Инфинитив – зат-сан, заман белән төрләнми торган фигыль формасы. Мәүла Колый хикмәтләрендә инфинитив *-мага/ -мәгә, -мақ/-мәк, -ырга/-ергә, -асы/-әсе* аффикслары ярдәмендә ясала. Мисаллар: Белмән үзем қанда мән / Йул таба алмаз чүлдә мән [МК. 32б]; Қабул қылсаң бәндә мән, Қоллығыңда тормаға [МК. 32б]; Ханә ғишқында әwарә, Дәрдем чуқ мән бичара / Йулың белмәз бичара, Хәзрәтеңә бармаға [МК. 32б]; Хақ нәфсани қылмаса [МК. 32б].

Аерым очракларда тулы бәет әлеге форма белән төзелә:

Күрсәм шәйхем үзене, Белсәм ғәзиз сүзене,
Көн балкыр тик йөзене, Күрмәгә мәңа тикәр?
Шәйхем-җаным гөлләре, Сайрайур былбыллары,
Ғишык ширбәтен эчеб, қанмаға кемгә тикәр?
Шәһидләрнең қаныни, Йумағайлар тәнене,
Хақ ғәзиз өчен җаныны, Вирмәгә кемгә тикәр?
Башы белә җаныңдин, Бизсә ханәм аныңдин,
Шәйех өчен қаныңдин Кичмәгә кемгә тикәр? [МК. 25].

Мәүла Қолый, шәйхең чөн, Тағларны күтәр, күчен, Баш, җан хезмәте өчен, Салмаға кемгә тикәр? [МК. 38].

*-мага/-мәгә* аффиксы әсәрләрдә инфинитивның төп формасы булып тора һәм түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

эш-хәлнен максатын: Ғишык ширбәтен эчеб, қанмаға кемгә тикәр? Кул йаратдың тотмаға [МК. 25б];

билгеле бер затның эш-хәлне башкару теләге, нияте мәгънәсен: Тунанмаға тун бирдең, қуанмаға мал бирдең, Йийеб қанмаға нан бирдең Ризық биргән Алла сән. Бирдүң данә сачмаға, ғыйлаҗ бирдең печмәгә, Йийеб-эчеб кичмәгә, ғомер биргән Алла сән. [МК. 25];

исем сүз төркеме белән килгәндә *-ырга/-ергә* формасы мәгънәсен: Ғәрибләргә тормаға йорт-мәкян қани [МК. 23].

М. Колый иҗатында берничә урында *-ырга/-ергә* аффиксы да урын ала: Гөнаһ тауғын йуарға су – тәүбәне бел [МК. 24]; Қәләмең уқырға қол йаратдың сән бези [МК. 12б].

XVII гасыр иске татар эш кәгазьләре телендә, киресенчә, хәзерге татар әдәби теле өчен норма саналган *-ырга/-ергә* кушымчасы базис форма булып тора: *таларга, таптурурга, бирүргә, йебәрүргә* [Маннапова, 1983, б. 94]. Бу документларда *-маска* кушымчалы юклык

формасы да актив, әмма ул күпчелек очракта боеру мәгънәсендә кулланыла: җүмләсен җауламасқа, түрлүк йаманлық қылмаска, ич нәрсә сорамасқа [Маннапова, 1983, б. 95]. Бу истәлекләрне ныклап өйрәнгән А. Маннапова *-мағa/-мәгә* формалы инфинитивның да әлеге эш кәгазьләрендә еш файдаланылуына мисаллар китерә: сақламаға қуйубтурлар, чыкмага бойормагай ирдүк, түләмәгә бойоргай ирдеңез [Маннапова, 1983, б. 94]. Инфинитивның *-мақ/-мәк* формасы да XVII гасыр иске татар эш кәгазьләре өчен ят түгел: эзләмәк, сорамак бойордылар 'эзләргә, сорарга боердылар' [Маннапова, 1983, б. 94].

XVIII гасыр язма истәлекләре телендә инфинитивның шулай ук *-рга/-ргә* һәм *-мағa/-мәгә* формалары актив кулланылышка ия.

*-мағa/-мәгә* формалы инфинитив XVIII йөз әдипләре әсәрләренең һәммәсендә кулланыла: Тәғәт кылмай йөремәгә бу дөнйада ни эшеңез [Габди. 18]; Һәр сүзеңә хәҗәт кылың, сүзләтмәгә киргәләб [Габди. 20]; Қанда wарсам күренергә қара йөз, Телем йуқ сүзләмәгә йарар сүз [ГМ. 154] һ.б. Соңгы мисалдан күренгәнчә, автор хәтта бер бәет кысаларында да ике форманы янәшә файдалана. Г. Тайсугани иҗатында очрамый. Г. Утыз Имәни иҗатында инфинитив формасы актив түгел, әмма әлеге кушымча шулай ук төп форма буларак кулланыла: нәчә йирдә алыр чолғап арыслан қо тылмаға қоралсыз улмаз аслан [УИ. 50]; Әһле мәзарәт бәйане җәһед қылырға әйлә салихәтең өмидеңдин қалырга хәйлә табдың [УИ. 50]; кемсә килмәс қашыңа хал сорғалы, нәфсең эстәр төрлүк ашлар йийгәли [УИ. 66].

Рәсми документларда да очрый: Бойырылды ул Бәхтийар Җанқай уғлына палкавай ыстаршина булуп чирү хезмәтне қыйлмаға (175 б.), һәм борын атланғанлары булса һәм қайтармаға әмер итдүм... (172 б.) һ.б. Бу кулланылышны Ф.М. Хисамова диалекталь үзенчәлекләрнең чагылышы дип карый [Хисамова, 1981, б. 71]. Мәгълүм булганча, бу фигыль формасы татар теле сөйләшләрендә хәзер дә саклана [Татар халык сөйл., 2008, б. 103,164].

*-мақға* формасы бары тик Габдессәлам иҗатында бер урында күзәтелде: Иншалла, өмидем wар қаwышмақға сезләрә [Гс. 56]. Бу форма XVIII йөз язучылары телендә башка очрамады.

*-ырға/-ергә* кушымчалы фигыль әсәрләрдә, хәзерге әдәби телдәге кебек үк, һәм бәйле, һәм мөстәкыйль позициядә кулланыла: Йәшлегемдә башым салдым йүләргә, Әрнелгәнчә йитешеб мән үләргә [ГМ. 145].

Ф. Хисамова күрсәтүенчә, эш кәгазьләрендә, бары берничә урында көнбатыш диалект сөйләшләрендә хәзерге вакытта *бул-* фигыле белән генә очрый торган *-дачы* кушымчалы сыйфат фигыль нигезендә ясалган *-дачы бул* тасвирлама һәм архаик *-гүдәй бу*л формалары кулланылган: Әгәр дә инкяр вә хөҗҗәт идәче булсалар, һиммәт вә куәт кылып... (191 б.). Ул дошманлар илә безләр суғуш ғөмәлене қыйлурға хәлемез йитгүдәй булмады (205 б.) [Хисамова, 1981, б. 102].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, XVII гасыр поэзиясен, нигездә, Мәүла Колый иҗаты аша күз алдына китерәбез. XVIII йөз поэзиясе вәкилләре Габди, Габдессәлам, Габдерахман бине Туймөхәммәд Тайсугани, Хәлилулла, Максуд, Габделгафур бине Габделмәннан, Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари, Габделмәннан Мөслимов һ.б. ларның әсәрләре телен тикшеренүләрдән түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин. Әлеге чор әдәби телендә исемнәрнең килеш белән төрләнешен кыпчак төрләнеше тәшкил итә. Бу үзенчәлек тартымлы төрләнешкә дә карый. Алар, нигездә, тартымлы исемнәрнең төшем һәм юнәлеш килешләрендә күзәтелә. Аларга караган угыз формалары Мәүла Колый иҗатында сирәк очрый. XVIII йөз әдипләренең әсәрләрендә бу үзенчәлекләр арта төшә, әмма кыпчак формалары өстенлек итә. Шулай ук чыгыш килешенең борынгы уйгыр *-дыйн/-дин* формасы да Мәүла Колый хикмәтләрендә системалы кулланылышка ия булса, XVIII йөз әсәрләрендә, бигрәк тә, Г. Мөслимов иҗатында *-дан* формасы нык активлаша. Истәлекләрдә хәбәрлек категориясе кушымчалары хәзерге тел белән чагыштырганда активрак кулланыла. Сыйфатлар төрки-татар *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчалары белән ясала, шул ук вакытта фарсы *би-*, *на-* префикслары да актив. XVIII йөз поэзиясенең кайбер вәкилләре, мәсәлән, Габессәлам иҗатында сыйфатларның төрле семантик төркемчәләре урын ала, шул рәвешле әсәрләрдә сурәтләү алымнары да арта. Алмашлыкларның кулланылышы хәзерге татар әдәби теленә якын. XVIII йөз әдипләре телендә *мин, син* формалары күбрәк күренә башлый, әмма шул ук вакытта *безләр, сезләр* формалары, *без, сез* алмашлыкларының юнәлеш һәм төшем килешләрендә угыз формаларын куллануның артуы күренә. *Бу* күрсәтү алмашлыгының килеш белән төрләнгән очракларда Мәүла Колый иҗатында *м* варианты гына (*моның, моны, мондин, монда*) бирелсә, XVIII йөз әдипләре әсәрләрендә *б* варианты (*боның, боны, бондин, бонда*) да күзәтелә. Саннарның барлык төркемчәләре дә текстларда чагылыш тапмый, ә микъдар

саннарының үзенчәлекләрен әлеге хезмәтнең беренче томында карап үткән идек.

XVII–XVIII йөз язма әдәби теле фигыль формаларына гаять бай. Башка чор төрки язма истәлекләрдәге кебек үк, бу чор истәлекләрендә дә әле грамматик формалар катнаш хәлдә кулланыла. Шул чор татар гомумхалык сөйләм теле өчен хас грамматик формалар белән бергә, угыз яки борынгы уйгыр теле өчен хас булган формалар да очрый. Мәсәлән, *-учы* формасының уйгыр варианты *-гучы,* угыз телләре өчен хас *-мыш* яки *-дык* формалары кулланыла. Әмма статистик күзәтүләр күрсәтүенчә, бу чорда халыкның җанлы сөйләмә формалары акрынлап норма буларак ныгый бара.

# 5. XIX ГАСЫР – XX ГАСЫР БАШЫНДА ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ӘДӘБИ ТЕЛЕНЕҢ МОРФОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

## 5.1. Исем

Төрле тематик һәм семантик төркемчәләргә бүлеп карарга мөмкин булган сүзләрнең, предметлык дип аталган гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә лексик-грамматик яктан гомумиләшеп, морфологик яктан сан, тартым, килеш категорияләре хас булган, фигыль һәм башка сүз төркемнәре белән бәйләнештә ия, тәмамлык, аергыч кебек җөмлә кисәкләренең вазифасын үти ала торган исем сүз төркеменә караган сүз һәм сүзформалар [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 25–64], XIX гасыр – XX гасыр башында төрле жанр-стильдә язылган текстларда да кулланылышта була. Шуның белән бергә, әлеге сүз төркеменең һәр категориясендә үз дәвере өчен зарури үзенчәлекләрнең дә чагылыш табуы күзәтелә. Алар һәр категорияне тикшерү барышында каралды.

*Сан категориясе.* Грамматик категория буларак, мәгънәсе ягыннан, предметның бер яки бердән артыклыгын, ягъни билгесез күплеген белдерә торган сан категориясе, берлекне һәм күплекне белдерә торган формаларда чагылыш таба [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 34]. Гомумтюркологик хезмәтләрдә аңлатылганча, исемнәргә хас булган сан категориясенең формалашуында күплек төшенчәсенең тарихи үсеше чагылыш таба [СИГТЯ, т. II, 1988, с. 10]. Сан категориясе исемнең иң характерлы «абсолют» үзенчәлеге санала, чөнки «...исемнән башка сүз төркемнәренең сан белән төрләнүләре өчен, я исем белән бәйләнешкә керүләре (ярашулары), я исем урынына ки-

леп, исемләшүләре шарт» [Хангилдин, 1954, б. 64; Җәләй, 2000, б. 12; Благова, 1994, с. 250].

«Языки мира.Тюркские языки» дигән энциклопедик хезмәттә, язма истәлеге булу-булмауга карамастан, барлык телләрдә дә исемнәрнең берлек һәм күплек санда булуы турында мәгълүмат бирелә. Аерым авторлар *-лар/-ләр* кушымчасының төрле мәгънәләр белдерә алуына [Языки мира..., 1997, с. 163], гарәп-фарсы алынмаларының үз телләренә хас булган мөкинлекләре белән кулланылышына игътибар итәләр [Языки мира..., 1997, с. 152–153].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар теле фәнни яктан тикшерелеп язылган беренче хезмәтләрдә исемнәргә әле билгеле бер төркем итеп каралмый, аларда аерым сүзләргә хас булган үзенчәлекләр турында мәгълүмат бирелә. Г. Фәезхановның «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» дигән грамматикасында «Беренче фасыл исемләр бәянында» дигән баш астында, конкрет һәм абстракт мәгънәле исемнәр, хәзерге татар тел белемендә аңлатылганча билгеләнә: «Исем диб хариҗда йәки зиһендә бар булган нәрсәгә дәлаләт кылган кәлимәне әйтәләр. Хариҗда бар диб хәвасе хәмсә заһира, йәгъни күреб, ишетеб, тотыб, тәмләб, иснәб белмәк кораллары белән беленгән нәрсәләрне әйтәләр. Әмма зиһендә бар диб гакыл белән уйлаб беленгән нәрсәләрне әйтәләр, мәсәлән, фәһем, гыйлем кеби». Автор шулай ук исемнәрнең ялгызлык (исме галәм) һәм күмәклек (исме җенес) төрләрдә булуын, ягъни аерым бер төркем һәм бер җенестән булуына игътибар итә, әлеге сүзләрнең берлек һәм күплек саннарда кулланыла алуларын белдерә: «...Әгәр исемләр дәлаләт кылган нәрсә бер ялгыз булмый, бәлки ике йә андан күп булса, аны җәмгъ тәсмия диләр. Җәмгъ хасил була мөфрәднең ахырына ләмнең фәтхәсе белән бер لر- (*-ләр*) адәте тоташмак белән», – дип, күплек сан күрсәткеченең фәкать бер генә төрле булып язылырга тиешлеген искәртә [Фәизхан, 1887, б. 5–6; Фәизхан, 2005, б. 12–13]. Шулай итеп, татар теле фәнни яктан тикшерелә башлаган бу хезмәттә, исем дигәндә, телебездәге берлек санда һәм күплек санда була торган конкрет мәгънәле һәм абстракт мәгънәле сүзләр истә тотыла.

К. Насыйриның «Әнмүзәҗ» исемле хезмәтендә дә исемнәрнең «исме галәм йаки исме хас» (ялгызлык) һәм «исме җенес йаки исме гам» (күмәклек) исемнәренең, «исме гәйен» (конкрет) һәм «исме мәгънә» (абстракт) булып, «ма йәкүме бинәфсиһи» реаль яши торган сүзләр булулары турында әйтелә [Насыйри, 1895, б. 11–12; Насыйри, 1975,

б. 121]. Күплек кушымчасы (әдат җәмгы) турында «Исемнәрнең төрләнеше» («Играблар») дигән бүлектә бирелә: «Телемездә әдат җәмгы галәмәте тәфхим (авазны калынайтып, тутырып. – *И.Б.*) укыла торган кәлимәләрдә لار- (*-лар*) хәрфе булыр (исемләрдә вә фигыльләрдә), тәркыйк (нечкәртеп. – *И.Б.*) укыла торган кәлимәләрдә لر- (*-ләр*) хәрфе булыр (кәзәлик исемләрдә вә фигыльләрдә). Мәсәлән: قول – кул, җәмгы قوللار – куллар, كوز – күз, җәмгы كوزلر – күзләр [Насыйри, 1895, б. 66; Насыйри, 1975, б. 135]. Аңлашылганча, биредә хәзерге татар әдәби телендәге язылыш нормасы беренче мәртәбә кагыйдәләштерелеп бирелә.

Төрки телне төзәтүгә багышланган беренче Гыйльми мәҗлестә дә (Уфа, 1899) күплек кушымчасының язылуына игътибар ителә, унөч пункттан гыйбарәт булган карарның өченче пунктында болай диелә: «Җәмгъ галямәтләре улан لر- (*-ләр*), لار- (*-лар*) әдатлары, урынларына карап, һәр икесе истигъмал ителергә ...» [Курбатов, 1999, б. 35]. М. Өметбаевның «Татар нәхүсенең мохтәсары» (1901) китабында әлеге фикер кабатланып бирелә: «...Татар телендә ялгыздан күмәк сәхләчә, ягъни ансат була: каты сүзнең азагына لار- (*-лар*) кисәге кушыла. Мисал: قوللار – куллар, اياقلار – аяклар; йомшак сүзгә لر- (*-ләр*) кисәге кушыла. Мисал:كيملر – киемләр, كشيلر – кешеләр» [Өметбаев, 1902, б. 8] һ.б. Г. Ибраһимов хезмәтендә, күплек күрсәткече әлифсез вариантта гына язылырга тиеш дип белдерелә [Ибраһимов 1987, б. 36]. Кыскача анализдан аңлашылганча, биредә исемнәрнең күплектә ничек итеп язылырга тиешлеген кат-кат кагыйдәләштерергә омтылыш ясала. Шуңа да карамастан, «җәмгъ галямәтләрен», ягъни күплек кушымчасын файдалануда катгый бер ныклык формалашып җитми, аларны төрле авторларда төрлечә куллану дәвам итә.

XX гасырның урталарында, күплек санының формасы белән бергә, аның мәгънәсе турында да фикерләр әйтелә. Әлеге мәсьәлә В.Н. Хангилдиннең грамматикасында тәфсилләнә. «...берлек формасының семантик ягы, мәгънәсе, исемнең нинди лексик-семантик төркемчәдән булуына карап, төрлечәрәк була», – дип, автор ялгызлык, күмәклек, абстракт мәгънәле исемнәрдә берлекнең, һәм «...ялгызлык исемнәрдә күплек формасы, күмәклек исемнәрдәге кебек үк, үзләренең күплеген белдерми, бәлки аларга җыймалык оттеногы гына өсти», – дип, берлек белән күплек саны мәгънәләренең предметлык категориясе нигезендә берләшә торган лексик-семантик төркемнәрнең табигатенә бәйле булуын аңлата [Хангилдин, 1954, б. 65–66]. Авторның шул ук фикерләре «Хәзерге татар әдәби теле» дигән басмада да

чагылыш таба [Хәзерге татар ..., 1965, б. 191–192]. Академик татар грамматикасының морфологиягә багышланган томында да әлеге фикерләр нигез итеп алына. Ялгызлык исемнәре, конкрет һәм абстракт мәгънәле җыймалыкны, әйбер-матдәне белдерүче һәм микъдар саны белән дә кулланыла торган исемнәр предметлык категориясе нигезендә берләшә дип аңлатыла. Төрле лексик-семантик төркемчәгә карый торган сүзләрнең берлеге нуль форма белән белдерелә. Шул ук исемнәр *-лар/-ләр* кушымчасы белән дә кулланыла. Бу очракта күплек кушымчасы лексик-семантик төркемчәнең табигате белән мөнәсәбәттә төрле мәгънәдә һәм вазифада файдаланыла. Мәсәлән, конкрет мәгънәле исемнәрдә аларның билгесез күплеге, абстракт мәгънәле һәм җыймалыкны белдерә торган исемнәрдә аларның конкретлашуы, әйбер-матдә белдерә торган исемнәрдә аларның муллыгы белдерелә [Татар грамматикасы, т. II, 2002, б. 34–38].

Иске татар телендә язылган әдәби текстларда исем сүз төркеменә хас булган сан категориясе тикшерелгәндә дә, кабул ителгән фәнни нигезне саклау максатыннан һәм язма традициянең ничек итеп дәвам ителешен күз алдына китерү өчен, әлеге өйрәтү нигез итеп алынды.

Иске татар телен тикшерүче галимнәрнең хезмәтләрендә сан категориясе өйрәнелгәндә әлеге нигезләмәнең кайбер якларына игътибар ителә. Мәсәлән, Я.С. Әхмәтгалиеваның хезмәтендә берлек төшенчәсе берлек сандагы исем һәм *бер* саны *(бер халәлем),* берлек сандагы исем һәм *бу, ул* күрсәтү алмашлыклары *(бу баш, ул баш әйтүр),* тартым кушымчасы *(йөзе ай)* белән белдерелә дип аңлатыла. Күплек һәм җыймалык идеясенең *-лар/-ләр, -ан* кушымчалары *(ирән, дустан),* гарәп алынмаларында ватык күплек формасы *(сәхабә – әсхаб),* ягъни морфологик ысул белән, һәм шулай ук тагын берлек сандагы исемнең микъдар саны белән бергә *(биш намаз кылыр), аз, күп* кебек хәбрлек сүзләр белән, сүзләрне кабатлау *(парә-парә кисәкләр),* ягъни лексик-синтаксик ысул белән белдерелүе күрсәтелә [Ахметгалеева, 1979, с. 73]. Ә.Р. Исхакованың хезмәтендә, асылда, шушы ук фикер кабатлана [Исхакова, 2005, б. 69]. Б.К. Миңнуллинның монографиясендә күплек сан кушымчасы сүз тамырының (нигезенең) нинди авазга (хәрефкә) тәмамлануына мөнәсәбәтле рәвештә карала. Мисаллардан күренгәнчә, күплек кушымчасының фәкать әлифсез варианты файдаланылуы, ягъни сүзнең нинди авазга тәмамлануы күплек кушымчасының сыйфатына тәэсир итмәве аңлашыла [Миннуллин, 2012, с. 130–131]. Башка хезмәтләрдә сан категориясе берлектә һәм күплек-

тә чагыла дип, кыскача мәгълүмат кына бирелә [Исламова, 1998; Гарипова, 2003; Абдулхаков, 2010 һ.б.]. Аерым авторларның хезмәтләрендә [Маннапова, 1982; Мухаметрахимова, 1990; Хисамова, 1999; Нуриева, 2004 һ.б.] сан категориясен анализлау күздә тотылмый. А.Р. Йосыпов монографиясендә сан категориясенең гарәп-фарсы алынмаларында чагылышы мисаллар белән күрсәтелә [Юсупов, 2006, с. 44–46]. Р.Ф. Мирхәев хезмәтендә күплек төшенчәсенең аналитик ысул белән дә бирелешенә игътибар ителә [Мирхаев, 2007, с. 26–27]. Аңлашылганча, исем сүз төркеменә хас булган сан категориясенең иске татар телендә язылган әсәрләрдә билгеле бер системада, ныклы план белән язылмавы күренә, димәк, әлеге категориянең ничек итеп кулланышта булуын тикшерүне дәвам итү сорала.

Безнең максат – XIX гасыр – XX гасыр башы иске татар язма чыганакларында төрле лексик-семантик төркемнәргә караган исемнәрнең аерым авторлар тарафыннан берлектә һәм билгесез күплектә ничек итеп файдаланылуын тикшерү-анализлау. Кабул ителгән тәртипне саклау максатыннан исемнең лексик-семантик төркемчәләре, асылда, хәзерге татар грамматикасына нигезләнеп бирелде, әмма язма текстларда кулланылу үзенчәлеге истә тотылып, башта ялгызлык һәм абстракт мәгънәле исемнәргә игътибар ителде.

XIX гасырның беренче яртысында Әбелмәних Каргалый (1782–1833), Һибәтулла Салихов (1794–1867), Шәмсетдин Зәки (1825–1865), Габделҗаббар Кандалый (1797–1860) кебек татар халкының танылган шагыйрьләре иҗат итә. Боларның барысы да зур укымышлы дин әһелләренең вәкиләре буларак, үзләренең әсәрләрендә дә иҗтимагый тормышның дини-рухани ягын, аның үз истыйлях-терминнарын чагылдырырга омтылалар. Бу юнәлештә үз заманына хас булган аристократ-абруйлы әдәби телдә, ягъни телнең барлык тармакларында да гарәп вә фарсы алынмаларын мул файдаланып язу дәвам ителә. Димәк, предметлык дигән грамматик категориягә берләшә торган төрле сүзләрнең дә күбесен гарәп һәм фарсы алынмалары тәшкил итә. Гарәп-фарсы алынмаларының гасырлар дәвамында катгый рәвештә үз чыганак теле кануны буенча язылуы мәгълүм [Вәлиди, 2007, б. 55]. Сан категориясендә, гарәп теленә хас булганча, берлек саны – нуль форма, икелек саны – *-ан, -әйен,* «бөтен» күплек – *-ат, -ун, -ин, -ийат (-ият)* аффикслары белән, «ватык» күплек саны кушымчасыз, сүзне «ватып», аның сузыкларын алмаштыру ярдәмендә ясала» [Мәхмүтов, 1965, б 814–816], «...дөрес шәкелдә берлек санындагы исемнәргә

... му’әннәстә *-әтүн...*, җансыз җисемнәрне белдерүче исемнәрнең күплек санының дөрес шәкеле шулай ук *-әтүн*» [Зәйнуллин, 1998, б. 40]. Фарсы теленең кагыйдәсе буенча, күплек саны *-ан* аффикса белән белдерелә: ир-ирән, ол-олан [Ахметгалеева, 1979, с. 75; Благова, 1994, с. 251]. Шуның белән бергә, әлбәттә, бу әсәрләрдә, нуль формадагы берлек, *-лар/-ләр* кушымчасы белән күплек сандагы төрки-татар сүзләренең кулланылышы да дәвам ителә. Күплек кушымчасының алынмаларга кушылуы да күзәтелә. Димәк, бу әсәрләрдә сан категориясенең төрки-татар һәм гарәп-фарсы телләренә хас булган параллель ике нормада кулланылуына, норма вариантлылыгының асылда әлеге нигездә хасыйл булуына игътибар итәргә тиеш булабыз.

Исемнәрнең берлек санда кулланылышы, күрсәтелгән вакытта иҗат ителгән поэзия әсәрләрендә, ялгызлык һәм абстракт мәгънәле исемнәрнең эзлекле рәвештә файдаланылуында чагылыш таба. Ялгызлык исемнәре дигәндә, хосусан, бар һәм бер булган Аллаһ һәм аның 99 әсмаи-хөснә исме-әгъзамләренең кулланылышы игътибарны җәлеп итә: Йәд әйләрсәң Аллаһ (الله) исмене, зикре Хакдан [Каргалый, 1889, б. 2], Хак өчен, Хәлилнең, шәйи Аллаһ (لله), Аллаһ (الله) өчен, Хәлилулла, Хак Тәғалә (حق تعالي) [Каргалый, 1889, б. 3], Хак ризачычөн, Аллаһ (الله) өчен, хөкем идәр Хода (خدا) [Каргалый, 1889, б. 4], йа Илаһ (يا الله), ризаи Хакчөн [Каргалый, 1889, б. 5], раһы Хакны, Хак рәхмәтендин [Каргалый, 1889, б. 6], Раббе ғыйззәт (رب عزت), Хак Тәғалә, хәмед улсун Ходая (حمد اولسون خدايه), Хак рәхмәтене, Хак җаннарны, Ходаем, фазыйл Ходая, йа Рабби, Хак, Зөлҗәләл (ذوالجلال) [Каргалый, 1889, б. 7], Аллаһ (الله) хәзрәте, Хак Тәғалә [Каргалый, 1889, б. 8], Солтан Рабб, Аллаһ хитаб, нәби Хакдан, Хода-и Зөлҗәләл, Хак Тәғалә хәзрәте [Каргалый, 1889, б. 9] һ.б. Аңлашылганча, бар һәм бер булган Аллаһы һәм аның әсмәи-хөснә атамалары аерым сүз, сүзформа, сүзтезмә буларак кулланыла, әмма һәрвакыт берлек санда.

Һ. Салиховның «Китабе Мәҗмәгыл адәб» әсәрендә (1856, 1900), Ш. Зәки, Г. Кандалыйның поэма һәм шигырьләрендә, Г. Чокрыйның әсәрләрендә дә Аллаһы атамасы, башка ялгызлык исемнәре дә, төрлесендә төрле дәрәҗәдә чагылыш таба, төрле авторда төрле ешлыкта кабатлана, берлек санда файдаланыла.

Әлеге хезмәтләрдә ялгызлык исемнәре кебек үк гарәп һәм фарсы алынмалары белән исемләнә һәм чыганак тел кагыйдәсенә буйсынып языла торган абстракт мәгънәле, ягъни референты аңда-фикердә булган һәм санала алмый торган берлек сандагы күмәклек исемнәре дә мул

файдаланыла: афәт, җан, сөннәте, фәрех-шад, тараф, мал, иман, хитаб, ғыйтаб, мәхәббәт, өмид [Каргалый, 1889, б. 2–3], тәғам, ханә, тәдбирең, әмер, нәфсемез арзусы мөшәварәт, өммәт, ахирәт [Каргалый, 1889, б. 4], қуwәтеңне[Каргалый, 1889, б. 6], иғанәт, ғаләмнең, ризықың, рәхмәтең, ахирәтдә, мөэмин, кяферләр, ғатаң, нәwәл, мовәххид, халық, ғыйбадәт [Салихов, 1856, б. 2], ғазаб, аба, өммәһат, остаз, әғмәлем, доғаи хәер, ғайбәт, мөслимин мөслиматы, ғыйнәйәт илә тәүфиқең, җәнаб рәхмәтеңдин, дөнйа, мәкер, ғомрем [Салихов, 1856, б. 2] һ.б.

Җыйма исемнәр дигәндә, берлек санда бербөтен булып аңлашыла торган предметларның, затларның җыелмасын атый торган сүзләр истә тотыла. Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә, төрле катламга карый торган ялгызлык исемнәре еш кабатланган кебек, бу төркемгә карый торган сүзләр дә актив кулланыла: халық, мөэмин, мөслимин, мәҗлес, мөҗаләсәт, җәмәғат, җәмғыйәт, дәүләт, зөмрә, милләт [Каргалый, 1889, б. 12] һ.б.

Ш. Зәки шигырьләрендә: җиһанның халқы [Зәки, 2002, б. 29], зәһи дәүләт [Зәки, 2002, б. 31], зәққумдан халқымы сақла [Зәки, 2002, б. 34], мин теләрем кем шул қәwемең зөмрәсендән улмаға, җиһан халқы – қолымдыр [Зәки, 2002, б. 36], сәнең дәүләт күгенә бенмәде [Зәки, 2002, б. 38], оемаенча дәүләт әһленә кеше, кәнд-үзендән дәүләтә ирешмәде [Зәки, 2002, б. 40] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, абстракт мәгънәле, җыймалыкны һәм әйбер, матдә мәгънәләрен белдерә торган исемнәрнең барысы да диярлек гарәп-фарсы алынмалары булуы күренә, һәм алар, нигездә, берлек санда кулланылалар.

Г. Кандалыйның шигырь һәм поэмаларында да абстракт мәгънәле сүзләрнең күбесен гарәп һәм фарсы алынмалары тәшкил итә: ғыйлем, нурани, мөэмин, содур, җисмең, сахиб, мәҗлес, хозур [Кандалый, 1988, б. 71], wақыт, ғомер, рәүнәк [Кандалый, 1988, б. 72], җаһил, хәл, [Кандалый, 1988, б. 74], вөҗүд, әзәл, әғлә-ғарешә [Кандалый, 1988, б. 75], доға, сәләм, кәләм,өмид, ғақылым, сәҗдә [Кандалый, 1988, б. 388] һ.б.

Шуның белән бергә бу авторның әсәрләрендә татар теленең үзенең абстракт мәгънәгә ия булган сүзләре кулланыла башлый: тереклек, аждаһа [Кандалый, 1988, б. 71], қайғы [Кандалый, 1988, б. 72], қарғыш, ашқыну [Кандалый, 1988, б. 75], сағыш [Кандалый, 1988, б. 77, 100], йәтимлек [Кандалый, 1988, б. 79], йегетлек [Кандалый, 1988, б. 80], моң [Кандалый, 1988, б. 91], туғанлық [Кандалый, 1988, б. 96], исәнлек [Кандалый, 1988, б. 113] һ.б.

XIX йөзнең икенче яртысында иҗат ителгән поэзия әсәрләрендә дә абстракт мәгънәгә ия булган сүзләрнең кулланылышы төрле авторда төрле дәрәҗәдә дәвам ителә. Әлеге мәсьәләне төгәлрәк күзаллау өчен Г. Чокрый һәм М. Акмулла иҗатына күз салу сорала. Әлеге авторларның әсәрләрендә конкрет мәгънәле, ягъни референтын күреп, тотып, тоеп, татып, иснәп карарга һәм санарга мөмкин булган исемнәрнең дә байтагы алынмалар булуы, шул ук вакытта төрки-татар сүзләренең еш файдалануы күренә: қул, диңгез, сөт, сары май, йуллар, йир, йөрәк, татлы су [Акмулла, 1892, б. 2], болағы, чәйгә су, бала, сөткә [Акмулла, 1892, б. 10] һ.б.

Биредә конкрет мәгънәле сүзләр дә, абстракт мәгънәле сүзләр кебек үк, асылда, берлек санында кулланылалар. Ул сүзнең тамыры (нигезе) белән туры килә, ягъни нуль форма белән белдерелә. Шуның белән бергә, исем *бер* сүзе белән сүз тезмәсе рәвешендә кулланылып, берлек мәгънәсе лексик-синтаксик ысул белән дә белдерелә ала: бер илкеңә [Каргалый, 1889, б. 2], бер қапуны [Каргалый, 1889, б. 3]. Шуның белән бергә *бер* сүзе берлекне генә түгел, билгесезлекне дә аңлата: бер көнне, бер кешейә, бер әр, бер кеше [Каргалый, 1889, б. 2] һ.б.

«Кисекбаш китабы»н өйрәнгән Я.С. Әхмәтгалиева берлек мәгънәсе *бу, ул* кебек күрсәтү алмашлыклары һәм тартым кушымчалары белән дә белдерелергә мөмкин дип саный [Ахметгалеева, 1979, с. 75]. Г. Кандалый иҗатында берлек сандагы исемнәрнең *бу* алмашлыгы белән бергә кулланылуы күзәтелә: бу асыл қошны [Кандалый, 1988, б. 73], бу йирдә [Кандалый, 1988, б. 79], бу май [Кандалый, 1988, б. 80], бу чәй [Кандалый, 1988, б. 84], бу бала хәсрәтен [Кандалый, 1988, б. 92], һ.б. Шуның белән бергә әлеге алмашлык белән җыйма мәгънәдәге исемнәрнең күплек санда да кулланылуы күзәтелә: бу қайғулар [Кандалый, 1988, б. 73], бу илләрдә [Кандалый, 1988, б. 75], бу йегетлек [Кандалый, 1988, б. 80], бу хәсрәтләр [Кандалый, 1988, б. 93] һ.б. Димәк, күрсәтү алмашлыгы берлек төшенчәсен белдерә дип әйтергә ныклы нигез булмавы аңлашыла.

Микъдар саны белән килә торган исемнәр, гадәттә, берлек санда биреләләр: ике пул, ике пара, беӊ җәфа [Каргалый, 1889, б. 5], ундүрт кәз иде киңлеге, алтмыш аршин иде һәм биеклеге[Каргалый, 1889, б. 10], меӊ аваз илә [Зәки, 2002, б. 46] һ.б.

Шуның белән бергә, тикшерелә торган әсәрләрдә исемнәрнең берлек санда кулланылган лексик-семантик төркемнәренең барысының да күплек санда да файдаланылуы күренә. Бу очракта күплек

кушымчасы лексик-семантик төркемчәнең табигате белән мөнәсәбәттә төрле вазифа белән кулланылуын барлыкка китерә. Мәсәлән, Ә. Каргалый әсәрләрендә ул конкрет мәгънәле исемнәрдә билгесез күплекне белдерә: ирәнләр тажы, ошбу сүзләре [Каргалый, 1889, б. 2], كونلار – көнләр [Каргалый, 1889, б. 4] һ.б. Абстракт мәгънәле һәм җыймалыкны белдерә торган берлек сандагы гарәп вә фарсы алынмалары күплектә кулланылганда, аларның мәгънәсендә конкретлык сиземләнә: мөхибләр намыны [Каргалый, 1889, б. 3], ниғмәтләреме [Каргалый, 1889, б. 9], ғалимләр, заһидләр (زاهدلر) [Каргалый, 1889, б. 5], өммәтләремдә, равилар [Каргалый, 1889, б. 7] һ.б.

Кешенең парлы әгъза атамалары эзлекле рәвештә күплектә күрсәтелә: ике әлчү кәзләрен мәхкәм дотыб [Каргалый, 1889,б. 2], күзләреңе (كوزلارنكي) күр идәм [Каргалый, 1889,б. 3], күзләре илә күрүбән [Каргалый, 1889, б. 9], бағлайубан әлләрене (اللر يني) [Каргалый, 1889, б. 7] һ.б.

Үз чыганак телендә күплектә булган алынмалар өстәмә рәвештә *-лар/-ләр* кушымчасы белән кулланылалар: حر فاتلر ينه – хоруфатләренә (хәрефнең күплеге) [Каргалый, 1889, б. 2–5] һ.б.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыл адәб» әсәрендә: دليللر – дәлилләр [Салихов, 1856, б. 5], طالبلر– талиблар [Салихов, 1856, б. 10], ايشلره – эшләрә [Салихов, 1856, б. 7] һ.б.

Ш. Зәки шигырьләрендә: اللر – әлләр, كوكلر – күкләр, درويشلري – дәрвишләре, هلر,بند – бәндәләр, ايزكولر – изгүләр, قورقولر دن – куркулардан, صاتورلر – санурлар,يوللرنی – йулларны [Юсупов, 2006, б. 188, 190, 192] һ.б.

Г. Кандалыйның «Сахибҗәмал» поэмасында: سالملار – сәламләр, ينجولر – йенжүләр, يارلار – йарлар, بيللر – билләр, ايللر – илләр, كونكللر – күңелләр, نيجه لر – ничәләр, كيجه لر – кичәләр [Кандалый, 1884, б. 559].

Чыганакларда, исемнәр белән бергә, алмашлыклар һәм фигыльләр дә күплек санда файдаланыла ала. Бу очракта инде *-лар/-ләр* кушымчасының, лексик-семантик төркемчәләрнең мәгънәсен төрле төсмер белән баету вазифасыннан тыш, аерым әсәр эчтәлегендә тасвирлана торган күренешләрне хис-кичерешләр белән баетып, эмоциональ-экспрессив функция үтәү өчен дә файдаланылуы аңлашыла. Әлеге үзенчәлек һәр авторда үзенчә яңгыраш ала.

Күплек мәгънәсе *-лар/-ләр* кушымчасы белән генә түгел, күплекне, бергәлекне, тупланганлыкны, артыклыкны, җыймалыкны күрсәтә торган сүзләр белән сүз тезмәсе рәвешендә дә белдерелә: әһле ғадә (хәерчеләр төркеме), әһле залл (азгынчылар төркеме), әһле хәл

(көчле кешеләр), [Каргалый, 1889, б. 3], нәчә данаи даминә грифтар әйләяндер бу (күпме укымышлыларны тоткынга төшергәндер бу), нәчә ғалимләрең ғыйльмен һәбая иргезәндер бу (күпме галимнәрнең гыйлемен тузанга әйләндергәндер бу), нәчә заһидларың әғмәлене бадә вирәндер бу (күпме динлеләрнең гамәлен исерткечкә биргәндер бу) [Каргалый, 1889, б. 5], җыйыб ғайәт дә күб мал хәзинә [Каргалый, 1889, б. 6], камусының биһишт әйләя җаен (барысының урыны оҗмахта булсын) [Каргалый, 1889, б. 7] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, биредә күплек төшенчәсе исемнәр белән бергә кулланылган төрки-татар асыллы *нәчә*, *күб* сүзләре һәм гарәп-фарсы алынмалары булган *хәдд, пөр, әһле камус* (барысы) сүзләреннән торган сүз тезмәләре ярдәмендә белдерелә. Аналитик ысул белән белдерелә торган күплектәге исем өстәмә рәвештә *-лар* кушымчасын алган очракта (нәчә ғалимләр, нәчә заһидлар), күплек мәгънәсе конкретлык төсмере белән баетыла.

Биредә гарәп һәм фарсы алынмаларында күплек мәгънәсенең белдерелүен төрки-татар сүзләренең күплегенән аерып карау сорала, чөнки аларның «бөтен» күплеге *-ат, -ун, -ин, -ийат (-ият)* аффикслары белән ясала: همام المومنين – һиммам-әл-мөэминен (мөселманларның һиммәтлесе), әйләде дәғwәи әлwаһияте (دعواى الوهيتى) [Каргалый, 1889, б. 2], ال انا رب عالمين – инна рабб-ел-ғаләмин [Каргалый, 1889, б. 3], идәрмез истиғанәт (استعانت) [Салихов, 1856, б. 2], جميع مو منين و مو مناتى دخى هب مسلمين و مساماتى – җәмиғ му минин вә му минати дәхи һәб муслимин вә муслимати [Салихов, 1856, б. 3], اخوان – ихват [Салихов, 1856, б. 3] һ.б.

Шуның белән бергә язма чыганакларда «ватык», ягъни кушымчасыз ясалган күплек саны формасының да кулланылуы күзәтелә: дәүре әсхабе-дәүер [Каргалый, 1889, б. 3], әүляде сағыйрь [Каргалый, 1889, б. 4], әһле көффар [Каргалый, 1889, б. 5], әшрар (явызлар) [1889,б.11], همه اخفلد اخوال ايله خالات – һәммә әхфаде әхваль әйлә халәт [Салихов, 1856, б. 3] һ.б.

Әлеге формада килгән гарәп сүзләре тагын төрки телнең күплек кушымчасы белән дә кулланылырга мөмкин: انبيالار – әнбияләр [Каргалый, 1889, б. 3].

Фарсы теле алынмаларында күплек мәгънәсен белдерә торган *-ан/-ән* кушымчалы сүзләр шулай ук *-лар/-ләр* кушымчасы белән дә кулланыла:ايرانلار – ирәнләр [Каргалый, 1889, б. 2], اولانلر – оланлар [Салихов, 1856, б. 13] һ.б.

Ш. Зәки шигырьләрендә сан категориясе белән бәйле мәсьәләләр А.Ф. Йосыпов хезмәтендә җентекләп тикшерелә. Автор биредә күплек төшенчәсе, төрки-татар ысулына караганда, күпчелек очракта гарәп теленең «ватык» күплеге белән белдерелә дип, үзенең фикерен 25 мисал белән раслап куя [Юсупов, 2006, с. 44–46].

XIX йөзнең икенче яртысында иҗат ителгән поэзия әсәрләрендә күплек мәгънәсен белдерә торган кушымчаның бер үк вакытта эмоциональ-экспрессив төсмер дә өсти алуы күзәтелә. Г. Чокрыйның «Казан һәм аның халкы турында» дигән шигырендәге түбәндәге юлларда күплек кушымчасы, күплек идеясе белән бер үк вакытта, шагыйрьнең соклануын да күрсәтә: Иң әүwәл йортлары бик саф, икенче ирләре бик саф, өченче җырлары бик саф, әмерләре назар саздыр [Татар әдәбияты, 1957, б. 250].

М. Акмулланың «Даменла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе»ндә (1892) гарәп-фарсы алынмаларының күплеге, төрки-татар сүзләрендәге кебек үк, *-лар/-ләр* кушымчасы белән белдерелә: хасидләре, сабиқлардан, мөһәндисләр, башқалар, тәхқыйқларын батырлар, палуанлар [Акмулла,1892,б.2],батырларны [Акмулла, 1892, б. 3], мәргәнләрне, йегетләр, дәртсезләрнең [Акмулла, 1892, б. 4] һ.б.

Шуның белән бергә, алынмаларның күплеге гарәп теленең үз кагыйдәсенең төрле ысулларына нигезләнеп тә бирелә: мәғанә җаwаһирен (мәгънә гыйлеме җәүһәрләрен), әнһарул-хәқаикңы, голәмәгә [Акмулла, 1892, б. 2], әғдасенә, дәқаикда [Акмулла, 1892, б. 3] һ.б.

Г. Тукайның башлангыч чор иҗатында язма традиция дәвам ителә, төрки-татар сүзләренең дә, гарәп-фарсы алынмаларының күплеге дә *-лар/-ләр* кушымчасы белән күрсәтелә: җинниләр, юллары, дәүләтләр, саулэтләр, дәлилләр, журналлар, татарлар, аңсызлар, әүлядләр [Тукай, 1985, б. 24–25] һ.б. Алынмаларның күплеге үз чыганак теле кагыйдәсендә дә бирелә: баһаим дәфтәренә, журналларың әмсалини, әфкярә байлык, безез әсхабе, әүляде [Тукай, 1985, б. 24, 27, 28] һ.б. *-лар/-ләр* кушымчасының рәттән тезелеп кулланылуы авторның хис-кичерешләрен тасвир итү чарасы буларак аңлашыла. Алга таба күплек мәгънәсен белдерә торган кушымчаның эмоциональ-экспрессив төсмер белән хис-кичерешләрне тасвир итү чарасы буларак файдаланылуына Г. Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев һ.б. шагыйрьләрнең һәрберсеннән күп санлы мисаллар китерергә мөмкин.

XIX гасырның беренче һәм икенче яртысында иҗат ителгән тезмә әсәрләрдә, күплек кушымчасының калын һәм нечкә вариантларда

язылуында катгый бер система сакланмый, әлеге үзенчәлек төрле язучыда төрлечә чагылыш табып, графо-орфографик вариантлылык хасил итә. Ә. Каргалыйның «Тәрҗемани хаҗи...» әсәрендә билгесез күплекне белдерә торган *-лар* аффиксының әлифле вариантының (لار-) ешрак кабатлануы, аерым сүзләрдә әлифсез формасының да (لار-) кулланылуы күзәтелә: نجه الر – *нәчәләр* һ.б. Күплек төшенчәсе алмашлыкларда, исемләшкән сүзләрдә һәм фигыльләрдә дә шундый ук язылышта бирелә: ایدرالر – идәрләр, قیلدیلار –қылдылар,, دوردیلار – дордылар, اوتوردیلار – утурдылар, کندولاري – кәндүләре, ویردیلار – вирделәр, بونلارنك – бунларның, بزلار – безләр, بزلار ه – безләрә, جوقلاني – чуқларны [Каргалый, 1889, б. 2–5]. Мисаллардан күренгәнчә, сүзнең тамырында калын сузык булса да, нечкә сузык булса да, билгесез күплекне белдерә торган кушымча, асылда, бер генә төрле булып, ягъни әлифле формада гына кулланыла. Әмма берничә урында әлифсез вариантында да бирелә, ләкин аннан соң яңадан әлифле кушымча китә: وارالار – waралар,ویر ه لار – вирәләр دیدیلار – диделәр, اولدیلار – улдылар, ایلدیلار – әйләделәр, یولار نك – буларның [Каргалый, 1889, б. 5] һ.б.

Шуның белән бергә, «Өмми Камал китабы»нда «Мөнәҗәт әлхаҗи әбү әл-Мәних әл-Каргалый» һәм «Тәхрире әлхаҗҗел мәрхүм» дип басылган текстларда күплек кушымчасының әлифсез варианты ешрак кабатлануы күренә: ایدانلرني حکم – хөкем идәнләрне, جوقلر – чуқлар, کور کوزلرنکدن – күр күзләреңдән [Каргалый, 1884, б. 108–109, 112].

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыл адәб» әсәрендә дә күплек кушымчасы эзлекле рәвештә әлифсез языла: اولانلر – уланлар [Салихов, 1856, б. 2], کلورلر – кәлүрләр [Салихов, 1856, б. 8], مطبعلر – матбәгләр [Салихов, 1856, б. 14], اوقورلر – уқурлар [Салихов, 1856, б. 15], اتمزلر – итмәзләр [Салихов, 1856, б. 16], کلورلر – кәлүрләр, ایدرلر – әйдүрләр, صالورلر – салурлар, توبان لرکا – түбәнләргә, اولورلر – улурлар [Салихов, 1856, б. 17] һ.б. Әмма کافرلار – кяферләр [Салихов, 1856, б. 2], ایرنلار – ирәнләр [Салихов, 1856, б. 4] кебек исемнәрдә һәмاولارغه – уларга, شولارغه – шуларга, بولارغه – боларга [Салихов, 1856, б. 2–13] кебек күрсәтү алмашлыкларының күплек күрсәткече әлифле вариантта бирелә. Мисаллардан аңлашылганча, күплек кушымчасының формасына сүз тамырының калынлыгы яки нечкәлеге тәэсир итми, ягъни бирелә билгеле бер система саклана дип әйтеп булмый.

Ш. Зәки шигырьләрендә күплек сан кушымчасының, югарыда әйтеп үтелгәнчә, әлифсез варианты кулланыла [Юсупов, 2006, с. 188–193]. Г. Кандалый шигырьләрендә дә күплек кушымчасының, асылда,

әлифсез варианты кулланыла. Әлеге үзенчәлек шагыйрьнең Ж. Вәлиди тарафыннан төзелгән «Татар әдәбияты барышы» китабында (1912) урын алган «Сахибҗәмал» поэмасында да күзәтелә: سالاملر – сәламләр, اشلري – эшләре, بورونغيلر – борынғылар [Вәлиди, 1912, б. 94], نيجه لر ده – ничәләр дә, آشيلر ده – ашыйлар да, اجه لر ده – эчәләр дә, كيجه لر ده – кичәләр дә [Вәлиди, 1912, б. 95]. Мисаллардан аңлашылганча, сүз тамыры нечкә булса да, калын булса да күплек кушымчасының фәкать әлифсез формасы гына файдаланыла.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында иҗат ителгән поэзия әсәрләрендә күплек кушымчасы төрлечә языла. Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Бүз йегет» (1874) әсәре өчен, нигездә, әлифле язылыш хас: نورلى يوزلر – нурлы йөзләр [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 2], قزلار – қызлар, ايدىلار – иделәр, كونلار – көнләр [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 3], كشىلارى – кешеләре [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 4] һ.б. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1894) әсәрендә, сүз тамырында нинди сузык булуга карап, билгеле бер дәрәҗәдә аерымлану күзәтелә, әмма эзлеклелек сакланмый: آلتونلار – алтунлар, كموشلر – көмешләр, قايعولارى – қайғылары, تللر – телләр, بوسه لار – бүсәләр, ميو ه لر – мивәләр, چچاكلر – чәчәкләр, سوزلار – сүзләр, سوزلر – сүзләр, كوزلار – күзләре تللار – телләр [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 2–7] һ.б.

Г. Чокрыйның «Шәмгыз-зыя» (1883) китабында сүз тамырының нинди булуына карамастан, күплек кушымчасының, асылда, әлифле варианты кулланыла: احبابلارد – әхбәблары, مرثيهلار – мәрсиялар, دعالار – доғалар [Чокрый, 1888, б. 15] һ.б. Шул ук авторның «Замме назыйр» (1888) китабында исә күплек кушымчасының ике төре дә файдаланыла.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе»ндә (1892), алдагы әсәрләдәге кебек, бер үк сүзнең ике төрле язылуы күзәтелә: باترلار – батырлар [Акмулла, 1892, б. 2], باطرلارنى – батырларны [Акмулла, 1892, б. 3] һ.б., әмма, сүз тамырында нинди аваз килүенә карамастан, күплек кушымчасының әлифсез варианты ешрак кабатлануы күренә: يولار – юллар, يكتلر – йегетләр, شاعرلردن – шағыйрьләр, آدملرنى – адәмләрне, دوستلرده – дустларда [Акмулла, 1892, б. 6] һ.б.

Шулай итеп, XIX гасыр – XX гасыр башында иҗат иткән татар шагыйрьләренең әсәрләрендә берлек саны нуль формада, күплек саны сүз нигезенә әлифсез *-ла*р (لر-) һәм әлифле *-ла*р (لار-) аффиксы кушылып белдерелә. Гарәп һәм фарсы алынмаларында күплек мәгънәсе үз чыганак тел кагыйдәсенә буйсынса да, күпчелек очракта икеләтелгән күплектә, ягъни *-ләр/-лар* кушымчалары ярдәмендә дә

белдерелә. Күплек кушымчасының калын һәм нечкә булып язылуында катгый бер система сакланмый, әлеге үзенчәлек төрле язучыда төрлечә чагылыш таба. Димәк, исемнең берлеге һәм күплеге белдерелә торган сан категориясендә язма норма графо-орфографик яссылыкта вариантлылык хасил итә, дип әйтә алабыз.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында төрле жанр-стильдә язылган татар прозасында исемнең берлектә һәм күплектә кулланылуын, шигъри әсәрләрне тикшергәндәге кебек, предметлык категориясенә берләшә торган лексик-семантик төркемчәләрдә ничек итеп чагылуына мөнәсәбәттә тикшерү сорала.

Хикәят сөйләүчеләрдән ишетелгән хәбәрләр, яисә акыллы кешеләрнең сүзе дип язылган К. Насыйриның әсәрләре, традиция буенча, Аллаһы Тәгалә һәм рәсүлебез Мөхәммәт саллаллаһу галәйһи вәссәлам хәзрәтләренең исеменә салават вә дога белдереп башлана. Башка ялгызлык исемнәре, әсәрнең кайсы стильдә язылуына бәйле рәвештә, төрлечә файдаланыла. «Фәвакиһел-җөласә фил әдәбият» (1884) хезмәтендә сөйләнә торган новеллалар «Лоқман хәким әйтде», «Арсту әйтде», «Әйүб бине Гасан әйтде», «Аристолис хәким әйтде», «Ибраһим Әдһәмгә бер кеше әйтде» кебек аерым шәхесләр исеме белән башлана [Насыйри, 1975, б. 250] һ.б. Бу исемнәр барысы да берлек санда кулланыла. «Әбүгалисина кыйссасы»нда (1882) ялгызлык исемнәренең күплектә кулланылуы да күренә: «...ничә Искәндәрләрне золмәткә илтеп, хашиғ ләб белән қайтарды» дигән җөмләдә, ялгызлык исеменең күплектә бирелүе, Македонский – Искәндәр кебек дөньяны басып алырга теләүчеләрнең күбесенең хурлыкка төшүе дигән мәгънәдә аңлашыла [Насыйри, 1974, б. 222].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында иҗат итүче мәгърифәтчеләрнең әсәрләрендә дә, ялгызлык исемнәре белән рәттә, конкрет, абстракт мәгънәле, җыймалыкны, матдә-әйберне белдерә торган, ягъни төрле лексик-семантик төркемчәләргә бүлеп карарга мөмкин булган исемнәр файдаланыла. Алар һәм берлектә, һәм күплектә кулланылалар. Төрле лексик-семантик төркемчәгә карый торган сүзләрнең берлеге нуль форма, ә күплеге *-лар/-ләр* кушымчасы белән белдерелә. Бу очракта күплек кушымчасы хәзерге әдәби телдәге кебек аерым бер лексик-семантик төркемчәнең табигате белән бәйләнештә аның мәгънәсен төрле төсмерләргә баета.

Конкрет мәгънәле төрки-татар һәм гарәп-фарсы асыллы исемнәрнең берлеге затның, предметның бер данә булуын, *-лар/-ләр* кушым-

часы ярдәмендә ясалган күплеге билгесез күплеген белдерә: Мине ул уғры қулыннан кәнизәк дип сатып ал, ... падишаһ үзенең кәнизәкләренең берсенә әйтде [Насыйри, 1975, б. 224], ... инде кич чебен ник килсен, суғыш көнендә мал чығармақ, кич белән чебеннәргә бал чығармақ кебекдер [Насыйри, 1975, б. 227], ... вәзирем ғозер итте, бу вәзирләрдә ғаделлек юқтыр, ... минем ишәгем патшаның вәзирләреннән ақыллырақтыр [Насыйри, 1975, б. 242], бүлмәләр вә сөфәләр, ағар чишмәләр вә һәйбәт көтебханәләр бар иде [Насыйри, 1974, б. 213] һ.б.

Берничә мәртәбә берлектә кулланыла торган конкрет мәгънәле исем, *-лар/-ләр* кушымчасын алгач, шул исемнең күп затка каравы аңлашыла: шәһәрнең падишаһы хозурына китерделәр, падишаһлары бер надан адәм иде, надан падишаһ ... боларны үтермәгә әмер итте, ахмақ надан, батыйл падишаһ [Насыйри, 1974, б. 213] һ.б. Биредә «падишаһлары» дигәндә Саба һәм Багдад падишаһлары истә тотылып, «падишаһларга дога вә сәна» дигәндә, падишаһның ике, ягъни бердән күплеген белдерә [Насыйри, 1974, б. 224] һ.б.

Күплекне белдерә торган *-лар/-ләр* кушымчасы бер үк сүзләр чолганышында һәм абстракт, һәм конкрет мәгънәле берлек сандагы исемнең мәгънәсенә бернинди үзгәреш бирмичә дә кулланыла: ...бу мал барчасы минем малымдыр, мирасымдыр, ... бу маллар барчасы синең малыңдыр [Насыйри, 1975, б. 233], ... адәм сурәте нәқыш итеп тутыр, ул сурәтләрне ... зиннәтлә [Насыйри, 1975, б. 226], кергән халықлар, кешеләр [Насыйри, 1974, б. 212], халық боларны күреп, халық ғаҗиз булғаннар ... барча халықлар җыелып ..., дәррәү халық... [Насыйри, 1974, б. 213]. һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, абсолют бер үк сүзләр берлек һәм күплектә кулланылганда, аларның мәгънәләрендә үзгәреш күзәтелми. Әмма билгесез күплектәге исем *ул, бу* алмашлыклары белән (ул сурәтләр), яисә аергыч белән анықланганда, күплек кушымчасы тәгаенләнгән исемнең мәгънәсенә конкретлык төсмерен арттыра: ...биниһая кыйммәт һәдияләр хәзерләп, ... күндерделәр, ... қатқан бозлар шикелле, сақаллары шалтырап, урамларда очраған халық көлешеп, артларындан ияреп баралар, ... тәмам қыш көне кебек қарлар яуган, бозлар каткан [Насыйри, 1974, б. 38] һ.б. Бу үзенчәлек, әйбер-матдә белдерә торган исемнәрдә ачыграк чагыла: ...бер қапчық энҗе, җәүһәр вә төрле асылташлар яшереп қуйган идем, ... ул энҗеләрне урыныннан алып..., ... ул җәүһәрләр урынында җилләр исәр [Насыйри, 1974, б. 228], атаңның яшергән җәүһәрләре..., ... җәүһәрләрне чыгарып [Насыйри, 1974, б. 230] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, сүзләрнең берлектә һәм күплектә кулланылышы берсе икенчесенә бәйләнгән хәлдә бара, аерып алып тикшереп булмый. Күплек кушымчасы *ул* күрсәтү алмашлыгы, яисә башка ысул белән тәгаенләнгән әйбер-матдә исеменең мәгънәсен конкретлаштыра һәм аның муллыгын, таралышын белдерә. Гомумтюркологик хезмәтләрдә [СИГТЯ, 1988, с. 18] һәм хәзерге татар тел белемендә аңлатылганча [Татар грамматикасы, т. II, 1998, б. 248, 251], исемнәргә, сыйфатларга кушылып, җыймалыкны, туплануны белдерә торган *-лык/-лек, -лы/-ле* күрсәткечле абстракт мәгънәле сүзләр дә *-лар/-ләр* аффиксы белән кулланылганда, җыймалыкны белдергән берәмлекләрнең тагын да күләмлерәк булуын аңлата: олуғ ғыйлемлек, ниқадәр ғыйлемлек [Насыйри, 1974, б. 211], падишаһлық диваны [Насыйри, 1974, б. 219], аларның явызлықларыннан халық ғаҗиз булғанлар иде [Насыйри, 1974, б. 213] һ.б.

Шуның белән бергә, тар контексттагы, яисә бер үк җөмләдәге төрле лексик-семантик төркемчәләргә карый торган исемнәр эзлекле рәвештә күплек санда файдаланыла башлагач, *-лар/-ләр* кушымчасының эмоциональ тасвир барлыкка китерү өчен кулланылуы аңлашыла: ...җәннәт мисал бер бақча, агачларның әлван-әлван чәчәкләре ачылған, хуш awаз былбыллары сайрап, күшекләрендә кәнизәкләр вә гыйльманлар, вә туфрақлары, ғанбәр, ағар чишмәләре бар [Насыйри, 1974, б. 224] дигән җөмләдә төрле семантик төркемгә караган исемнәрнең күплектә кулланылуы хикәяләүне хис-кичерешләр белән баета. Шул ук контекстта фигыль һәм сыйфатларның да күплек санда кулланылуы эмоциональ-экспрессив төсмерне тагын да арттыра, хикәяләүнең көен, ритмын билгели.

Хикәяләүнең үзенчәлекле ритмы барлыкка килүгә әлеге әсәрләрдә исемнәрнең *вә* теркәгече белән кулланылуы да йогынты ясый. *Вә* теркәгече белән парланып кулланыла торган сүзләр икесе дә берлек, яисә икесе дә күплек санда, яки икенче исем генә күплектә килергә мөмкин: бу чақлы нәсыйхәтләр ишетдең вә бу чақлы ғыйбрәтләр күрдең, патша вә бәкләр, вәзирләр вә бәкләр, хәйләләре вә ялғанчылықлары [Насыйри, 1975, б. 239] һ.б. Әлеге алым язучы тарафыннан «Әбүгалисина кыйссасы»нда яратып кулланыла: ғыйлем вә әдәп үгрәнмәгә, зирәк вә үткен зиһенле, мәҗлесләрдә вә сохбәтләрдә, фәһем вә фирасәте [Насыйри, 1974, б. 208], шәһәрнең изгеләре вә ғалимләре, вә пәйғамбәрләр вә әүлияләр каберенә [Насыйри, 1974, б. 209], күп ғыйззат вә хөрмәтләр күрсәтте [Насыйри, 1974, б. 215] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, *вә* теркәгече белән күбрәк берлек һәм күплек сандагы абстракт мәгънәле исемнәрнең парланып кулланылуы мәгълүм. Аерым очракта алар төрки-татар сүзләре белән тәрҗемә дә ителеп бирелә. Шул рәвешле хикәяләүнең үзенчәлекле көе эзлекле рәвештә дәвам ителә: Мең төрле хуш аwазлы сайрар қошлар хәмед вә сәна әйтерләр. Сәрби вә санәүбәр ағачлары башларын һаwаға чығарып, ботақлары зифа ярлар кебек, җил белән җилфердәй торған бер җәннәте абад, үлекләргә җан кертә торған бер бакчадыр ки... [Насыйри, 1974, б. 263]; ...қыйммәтле асыл затлар, хисапсыз алтын вә ташлар күрсәтте [Насыйри, 1975, б. 233].

*Вә* теркәгече белән теркәлгән ике исемнең соңгысының күплектә кулланылуы К. Насыйриның балалар өчен язылган һәм фәнни хезмәтләрендә эзлекле күзәтелә: яхшы вә яман нәрсәләрне, җан вә күңел хафачылықлары, моғтәбәр вә бай адәмләр (Тәрбия китабы), ғарәби вә мөшкел лафызлар, хуш вә яхшы мисаллар (Кабуснамә), адәмнең җисемен вә әғзасының қыйтғаларын (Мәнафигъ әл-әгъза), җир-су, диңгез вә тауларның, муафиқ вә килеше торган сүзләрне, унлап җәғрәфия вә тәварих китапларындан (Ысулы җәгърәфия кәбир), сарыф вә нәхү кагыйдәләрен (Әнмүзәҗ), тасныйф вә имля қагыйдәләре китабәт вә язу дигән нәрсә ... кәлимәләр вә гыйбарәләрдер, ғыйлем вә фән лөғатьләре (Кавагыйде китабәт), сарыф вә нәхү уқыған кемсәнәләр, сарыф вә нәхү уқымаған егетләр (Нәмүнә вә әнмүзәҗ] һ.б.

Әлеге үзенчәлек Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда да күзәтелә: ғақыл вә фазыйллар, хикәят вә тәмсилятлар, ғалим вә дана кешесе, мәқбул вә мәшһүр булды, бәйет вә шиғырьләрене, хосусияте вә ғалякасы, мал вә ниғмәт [Фәизхан, 1896, б. 2] һ.б.

Югарыда китерелгән аерым мисаллардан күренгәнчә, төрле лексик-семантик төркемчәләргә караган исемнәр күплек санда кулланылганда, һәр аерым төркемчәнең табигатенә бәйле булган мәгънә төсмере ала, тулаем әсәрнең көен-ритмын һәм экспрессияне барлыкка китерә, авторның эмоциональ мөнәсәбәтен чагылдыра. Биредә поэзия әсәрләрен тикшергәндәге кебек аерым төркемчәләргә караган сүзләрне барлау-теркәү ысулының прозаны тикшергәндә кулай булмавы аңлашыла, чөнки аларның мөмкинлеге вакыйгахәлләрне хикәяләп бару юнәлешендә ачыла. Эш барышында әлеге табигый халәтне сакларга, ягъни сан категориясенең чагылышын хикәяләү стиленә мөнәсәбәттә, нинди вазифа үтәвенә нисбәтән карау сорала.

Чыганакларда берлек һәм күплек төшенчәләренең аналитик ысул белән дә белдерелүе күренә. Берлек саны, гадәттә, *бер* саны белән күрсәтелә: бер табақ бал китерде [Насыйри, 1975, б. 227], бер ел шул шәһәрдә қалып, бер данәсене қапсалар, бер ел тәмам булғач, [Насыйри, 1974, б. 212] һ.б. Аерым очракларда *бер* саны билгесезлекне дә белдерә: бер почмақта калып [Насыйри, 1974, б. 212], бер күл бар иде, бер сәбәп кирәк [Насыйри, 1974, б. 214], бер олуғ шәһәр бар иде [Фәизхан, 1896, б. 2], асла бер баласы килмәгәнлекдән, бер доғасы қабул булған кешене ишетсә, вә қайда бер мөбәрәк урын бар диб хәбәр алса, бер ғазиз қарт килеб [Фәизхан, 1896, б.3] һ.б.

Микъдар саны белән килә торган исемнәр дә эзлекле рәвештә берлек формасында, әмма үзләре ачыклый торган исемнең күплеген белдереп, кулланылалар: мең төрле тәхсин уқыды [Насыйри, 1975, б. 227], йөз мең алтыннан хәерледер [Насыйри, 1975, б. 231], мең җан белән ғашыйқ булды [Насыйри, 1975, б. 233], қырық көн, өч сәғать [Насыйри, 1974, б. 212], ике падишаһның [Насыйри, 1974, б. 225], мең үкенечләр белән [Насыйри, 1974, б. 231], мең җаным белән, мең бәла белән [Насыйри, 1974, б. 232], мең ақча садақа [Фәизхан, 1896, б. 3], мең җан белә ғашыйқ булуб, сиксән изгү кешене, мең алтын сәрмәйә алуб [Фәизхан 1896, б. 4] һ.б.

Күплек саны *ничә* санау алмашлыгы, *күп* күләм-чама рәвеше, бөтенлекне белдерә торган *җәмиғ* алынмасы һ.б. лексик чаралар белән белдерелә: ничә еллар ғыйлем хасил итеп, ... күп мәмләкәтләрне вә шәһәрләрне үтеп [Насыйри, 1974, б. 209], әмеренә мотыйғ булғач, ... күп ғозерләр үтенеп, ... күп қыйммәтле бүләкләр белән, ... күп ғыйзззәт вә хөрмәтләр күрсәтте; җәмиғ (барлык) китапларын бер йиргә җыеп вә җәмиғ китапларын күздән үткәреп. [Насыйри, 1974, б. 211] һ.б.

Гарәп-фарсы алынмаларында күплек төшенчәсе *-лар/-ләр* кушымчасы белән дә, үз чыганак теле кагыйдәсенә туры китерелеп тә бирелә: ...җәмиғ мәхлукат (мәхлукның күплеге) [Насыйри, 1974, б. 210], хөҗрәнең этрафы (тарафның күплеге) [Насыйри, 1974, б. 220, 226], әғйәне солтанат (патшалыкның аристрократлары) [Насыйри, 1974, б. 221], ... әлфаз гайре мөтәнаһия белән сүз озайтып [Насыйри, 1974, б. 237] һ.б. Бер үк исемнең берлек һәм күплек саны парланып кулланылганда да күплек төшенчәсе бирелә: вәзир-вөзәрәсе белән [Насыйри, 1974, б. 1974, б. 215, 216] һ.б.

Чәчмә әсәрләрдә *-лар/-ләр* кушымчасының язылышында, шигырьләрдәге кебек, графо-орфографик вариантлылык күзәтелә. К. На-

сыйри, үзенең теоретик фикеренә тугрылык саклап, төрле жанр-стильдә язылган барлык хезмәтләрендә дә арткы рәт сузыклары белән язылган сүзләрне күплек кушымчасының әлифле варианты, алгы рәт сузыклары белән язылган сүзләрне күплек кушымчасының әлифсез варианты белән бирә: کلمەلر – кәлимәләр, آوررولار – аwырулар, کنەکەلردە – кенәгәләрдә, علاملر – ғалимләр, کتابلار – китаблар [Насыйри, 1881, б. 2], آدملر – адәмләр, حکاینلر – хикәятләр, روایتلر – риwайәтьләр [Насыйри, 1898, б. 2], کتابلارندان – китабларындан, بلماکانلر – белмәгәнләр, کشیلر – кешеләр, سوزلری – сүзләре, مسلمانلار – мөселманлар[Насыйри, 1898, б. 3] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда да күплек сан күрсәткече, нигездә, әлифсез варианты белән кабатлана: اهللر – әһелләр,ی کتابلر – китаблары, ترکلری – төрекләре, شهرلر – шәһәрләр, آؤللر – аwыл-лар, کونلر – көнләр, دستلر – дустлар, یافرا قلرد – йафрақлары, ایشلر – эшләр, قرنداش روغلری – қарендәш ыруғлары [Фәизхан, 1896, б. 2–4] һ.б. Т. Яхинның «Сабый вә сабыялар өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр ... « (1897) җыентыгында исә, күплек кушымчасы, нигездә, К. Насыйри тарафыннан кагыйдә итеп бирелгән тәртиптә языла: ملتلر – милләтләр, قوشلار – ғошлар, سوزلر – сүзләр,ماللار – маллар һ.б. Т. Яхинның «Тәгълимел-әдәб-иләл-вәләд» исемле дидактик хезмәтендә (1898) дә күплек кушымчасы сүз тамырындагы сузыкка бәйле рәвештә чагылыш таба: شیلر – шәйләр, قوللار – қуллар, قللار – қоллар, ادمیلر адәмиләр [Яхин, 1898, б. 3–4] һ.б.

Беренче драма әсәрләрендә, аерым алганда Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» (1888) драмасында күплек кушымчасы, сүз тамырының нинди булуына карамастан, я әлифле, я әлифсез булып языла: قورالار – қораллар, بایلر – байлар, حاتونلار – хатунлар, قوناقلر – қунақлар [Халиди, 1888, б. 2–3] һ.б.

Ш. Тукаевның «Тарихы Эстәрлебаш» (1899) хезмәтендә күплек кушымчасының вариантлары сүз тамырындагы сузыкка бәйсез рәвештә кулланыла: کشیلر – кешеләр, یللرده – йылларда, کمسەلر – кемсәләр, باقچەلرده – бақчаларда, باقچەلارد – бақчалары [Тукаев, 1899, б. 2–3] һ.б.

Шулай итеп, татар прозасы өчен хас булган хикәяләүнең беренче төрендә, ягъни риваять кылучылардан, акыллы кешеләрнең китапларыннан алынып, асылда, гарәп яки фарсы теленнән төрки телгә тәрҗемә ителеп язылган кыйссаларда сөйләнелә торган вакыйгахәлләрне укучыга җиткерү өчен исем сүз төркеменең сан категориясенә хас булган барлык мөмкинлекләре файдаланыла, лексик-семантик төркемчәләрнең һәммәсе дә диярлек һәм берлек, һәм күплек

санда кулланыла. Гарәп-фарсы алынмаларының күплеге үз чыганак теле кагыйдәсе буенча «төзек» һәм «ватык» күплектә бирелә, шуның өстенә бу сүзләр тагын *-лар/-ләр* кушымчасын белән дә кулланылалар. Шигъри әсәрләрдән аермалы буларак, чәчмә әсәрләрдә берлек һәм күплектәге исемнәр тар контекстта бер-бер артлы кабатланып файдаланылалар, бу очракта *-лар/-ләр* кушымчасының, морфологик вазифасы белән бер үк вакытта, хикәяләүне хис-кичерешләргә төреп, көчле экспрессив-стилистик функцияне [Благова, 1994, с. 257] белдерүе дә ачыграк күренә. Әлеге нигездә, хикәяләүнең аерым әсәр өчен генә кирәк булган көе-ритмы да хасил була. *-лар/-ләр* кушымчасының язылышында графо-орфографик вариантлылык дәвам итеlә.

Әсәрдә бара торган вакыйганы авторның үз исеменнән сөйләп бару ысулы, ягъни татар сәнгатьле прозасында икенче төр хикәяләү алымы, М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романы белән башланып (1886), З. Бигиев, Ф. Кәрими, Р. Фәхретдин, Г. Гафуров-Чыгтай һ.б. әдипләрнең әсәрләрендә дәвам итеlә. Авторлар укучыга риваять булып килә торган гомум билгеле хакыйкатьне түгел, чынбарлыкта булырга мөмкин хәлләрне бәян итәләр. Әсәрдәге вакыйгалар барышы конкрет авторның шәхси сөйләменә һәм аны тыңлаучы укучы мөнәсәбәтенә нигезләнә. Әлеге үзенчәлек, беренче чиратта, Аллаһы Тәгалә һәм Мөхәммәт саллаллаһу галәйһиссәлламне мактау шәкелен, ягъни традиция булып килә торган ялгызлык исемнәрен куллануны юкка чыгара. Әсәрнең башламындагы илаһияткә бәйле булган ялгызлык исемнәре юкка чыгарылуга карамастан, вакыйга барышында, сүз җаена туры китереп, Аллаһы Тәгаләне, аерым аятьләрне, дини хезмәтләрне телгә алу дәвам итеlә. Ялгызлык исемнәре дигәндә, әдәби әсәрләрнең атамасы итеп төп персонажның исеме куелуга игътибар итәргә тиешбез. Бу үзенчәлек, асылда, беренче төр хикәяләүдән билгеле алым (Әбүгалисина, Тутый), әмма бирелә алар әсәрнең жанры (кыйсса, намә) белән бергә үрелеп бирелә. Икенче төр хикәяләүдә әсәрнең исеме итеп куелган конкрет кеше һәм аның белән бәйле хәл-әхвәлләр турында мәгълүмат бирелүгә ишарәт итеlә («Хисаметдин менла», «Әлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә», «Сәлимә, яки Гыйффәт», «Әсма, яки Гамәл вә җәза» һ.б.). Хикәяләү барышында башка персонажларның исем-фамилияләре, дәрәҗәләре, алар яши торган шәһәр, авыл атамалары да файдаланыла. Хәзерге татар әдәби телендәге кебек бу атамалар берлек санда киләләр, сирәк очракларда күплек санда да кулланылалар. М. Акъегетнең романында «Хисаметдин менла

Зурколаковларга килде» дигән җөмләдә, ялгызлык исеменең күплектә кулланылуы гаилә дигән җыйма мәгънәне аңлата [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 84].

Конкрет, абстракт мәгънәле, җыймалыкны, әйбер-матдәне белдерүче һәм микъдар саны белән дә кулланыла торган исемнәр һәм берлектә, һәм күплектә файдаланыла. Төрле лексик-семантик төркемчәгә карый торган сүзләрнең берлеге нуль форма белән белдерелә.

Шул ук исемнәрнең барысы да, *-лар/-ләр* кушымчасы белән дә кулланылалар. Бу, хәзерге әдәби телдәге кебек үк, асылда, семантик төркемчәнең табигате белән бәйләнештә аның мәгънәсенең төрле вазифа белән кулланылуын барлыкка китерә. Тикшерүләр күрсәткәнчә, әдәби әсәрләрнең авторлары, төрле сәбәпләр аркасында, әлеге мөмкинлекне күп төрле вариантларда файдаланалар. Тезмә әсәрләрдән аермалы буларак, чәчмә әсәрләрдә лексик-семантик төркемчәләр, гадәттә, берсе икенчесе белән бәйле хәлдә кулланылалар. Әмма бу үзенчәлек тә, вакыйганың ничек итеп хикәяләнүенә бәйле хәлдә, төрле авторда төрле вариантлар хасил итә.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында, абстракт һәм җыймалыкны белдерә торган гарәп-фарсы алынмаларының күплеге чыганак теле кагыйдәсе буенча төзек һәм ватык күплектә бирелә: исламият [Акъегет, 1886, б. 4, 14, 16, 23]; қарйәнең әһалисе [Акъегет, 1886, б. 2], әхбаре җәдидәдән (яңа хәбәрләрдән) [Акъегет, 1886, б. 15], әхwәлдән сөйләңез [Акъегет, 1886, б. 17], Аурупа өдәбасы [Акъегет, 1886, б. 20], исляхат йулында [Акъегет, 1886, б. 31], ақча вә әшйадан (әйберләрдән) [Акъегет, 1886, б. 49] һ.б.

Биредә төзек һәм ватык күплектә килгән гарәп-фарсы алынмалары мәгълүмат бирү чарасы буларак файдаланыла.

Конкрет мәгънәле исемнәрнең берлеге – предметның бер данә булуын, *-лар/-ләр* кушымчасы билгесез күплеген белдерә: *ханә – ханәләр, хезмәтче – хезмәтчеләр* һ.б. Күплек төшенчәсе эзлекле рәвештә эчтәлегендә микъдар (чама, үлчәм, сан белдерелү) мәгънәсе булган *чук, хили, җәмигъ (барлык), җөмлә (барысы), әскәр (күп)* һ.б. төрки-татар һәм гарәп-фарсы алынмалары белән дә белдерелә: чуқ халық, чуқ халықлары, чуқ адәм, чуқ сәвән, чуқ йазық,чуқ тәгаҗҗебдер, чуқ wақыт, чуқ фәна, хили халық, җәмиғ аwыл, дәүләт чуқ, чуқ кәлмәсе һ.б. Исемгә генә түгел, башка сүз төркемнәренең дә күләмчамасын белдерә торган *чук* рәвеше, җанлы сөйләмдәгечә, *күп, бик* рәвешләре белән чиратлаштырыла башлый: бик ризықлы вә бәхтияр

улды, чуқ булындығы, бик шат улыр иде, күп халық [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 58] һ.б.

Шуның белән бергә, К. Насыйри прозасыннан аермалы буларак, бу төр хикәяләүдә бер үк исемнең янәшә килгән ике җөмләдә берлектә һәм күплектә файдалану ысулы әсәрнең көен, ритмын билгеләрлек дәрәҗәдә булмый, чөнки әкияти сөйләм гадәти сөйләмгә күчә бара: «Н» қарйәсенең ханәләре ғади ханәләр кеби ағачдан йасалмышдыр, йырақ дәгел бер кежүк ханә вар, бу ханә үзе кежүк булса да [Акъегет, 1886, б. 2], бер хезмәтче тотса да, башқа хезмәтчеләр ялласа да [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46] һ.б.

Ике исемнең *вә* теркәгече белән парланып, әсәрнең ритмын-көен барлыкка китерү мөмкинлеге дәвам итеlә, әмма төрле авторда төрле ешлыкта кабатлана: эш вә тиҗарәт өчен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 45], ... хәрәкәт вә кәсеп сәвән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46], биек буены вә ию қыяфәтене [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48], дин вә дил қардәшләремез, наданлық вә һөнәрсезлек, чуқ язық вә тәгаҗҗеп [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48], наданлық вә ғафләттән көләләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 49] олуғ вә мәйдан [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50] һ.б. Исем парлар белән рәттән сыйфат парлар, фигыль парлар тезелеп китә. *Вә* теркәгече белән теркәлгән ике сыйфатның сыйфатланмышы да күплек санда була: бөек вә бай адәмләр, нурлы вә күк күзләре, яхшы вә баерақ кешеләрне [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50], туғры вә хақыйқать [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51], сәрхуш вә исерек берничә ярамаз адәмләрнең һ.б. *Вә* теркәгече *һәм* белән чиратлашырга мөмкин: бөек һәм мәшһүр төҗҗар иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 52]. Аерым очракларда әлеге парлар тагын да киңәйтелә: кечек сақалы вә мыеқлары вә кечек чәче [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46] һ.б. Нәтиҗәдә берлек сандагы парлы исемнәр күплек санда кулланыла башлый: саче вә күзләре вә қашлары ялтыравық қара [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50], диванлар вә өстәлләрдә хили халық: төҗҗәр вә гавам утырмыш [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51] һ.б.

Аерым урыннарда күплек сандагы исемнәр эзлекле булып тезелеп бирелә башлый: Ашханәдә ғайрәт вә хәрәкәт башланды: қоймақлар, пәрәмәчләр бер-бер артлы пешмәйә башладылар, қамырлар басылып, қатламалар, қош телләре хәзерләнмәгә башладылар. Хезмәтчеләр, ашчылар олуг хәрәкәттә. Тиз заман ашханәдә янә хәрәкәт қупды: шурпалар, пылаулар қунақлар өчен қайнап-қайный

[Акъегет, 1886, б. 34]. Күренгәнчә, *-лар/-ләр* аффиксы конкрет, абстракт мәгънә, әйбер-матдә белдерә торган исемнәргә кушылып, аларның рәттән күплек санда файдаланылуын барлыкка китерә. Шул рәвешле аларның күплеге, муллыгы, төрлелеге белдерелә һәм бер үк вакытта авторның сурәтләнә торган күренешкә карата ирония катыш мөнәсәбәте тасвир ителә. Иониянең асылы шунда ки, хикәяләү барышында бу тырышлыкларның урынсыз булуы ачыла. Берлек санда бара торган исемнәрнең күплектә кулланылуы белән сөйләүченең хис-кичерешләрне белдерүе, К. Насыйри, Г. Фәезханов әсәрләрендә дә күренде, әмма бу очракта ул катлауландырыла, ягъни автор тарафыннан уңай дип сурәтләнә торган күренешнең, асылда, киресенчә булуы аңлашыла, һәм мәгълүм алымның тасвирлау вазифасы тагын да киңәйтелә, көчлерәк яңгыраш ала. Шулай итеп, татар прозасын хикәяләүнең икенче төрендә күплек саны алган сүзләрнең эзлекле кабатлануы җанлы сөйләм, халык авыз иҗаты ысулынча хис-кичерешләрнең муллыгын белдерә, сөйләмне җанландыра. Шулай итеп, аның тыңлаучыга-укучыга да көчлерәк тәэсир итү вазифасын тагын да катлауландыра. Шуның белән бергә күплек кушымчасының хөрмәтләү, олылау кебек вазифасы яңартыла: Хәзрәте рәсүл саллаллаһе галәйһи вә сәллам хәзрәтләре димешләрдер ки, кәндүсе чөн бер кемсә сорамакдан бер қапу ачса, Алла хәзрәтләре ачар аңа фәкыйрьлекдән йитмеш қапу [Акъегет, 1886, б. 17], «Н» карйасына қайтамыз хөрмәтле уқучыларым [Акъегет, 1886, б. 12], хөрмәтле уқучыларымның зиһенләрен арытмақдан чәкенеб [Акъегет, 1886, б. 50], Гыйззәтлү Хисаметдин хәзрәтләре! мәгыйшәтнең зәхмәтләрене онытып, һәм нәқадәр мосахәбәтләреңездән яхшы әфкярлы, ислам сәвән улдықыңызны аңламыш исәм дә [Акъегет, 1886, б. 26] һ.б.

Татар прозасында икенче төр хикәяләүне башлаган «Хисаметдин менла» романында сан категориясен файдалануга караган яңалыклар башка мәгърифәтчеләрнең әсәрләрендә дә дәвам ителә.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында (1887) *җәмәгать*, ягъни кешеләр төркеме дигән җыймалыкны белдерә торган исем, алты-җиде мәртәбә кулланылгач, *җәмәгатьләрнең* дип бер мәртәбә кабатлана да, яңадан *җәмәгать* дип язылу дәвам ителә [Бигиев, 1991, б. 236–237]. *-лар* кушымчасы алып, күплек санда кулланылганда, җыймалыкны белдерә торган гарәп алынмасының икеләтелгән күплектә файдаланылуы аңлашыла. Бу очракта ул *күп кешеләр* тезмәсе белән тәңгәлләшә һәм чиратлаша. Хикәяләүнең беренче төрендәге

кебек абстракт мәгънәле бер үк сүзнең берлек һәм күплек санда кулланылуы хикәяләүнең ритмын барлыкка китерер дәрәҗәдә кабатлана дип әйтеп булмый. Гарәп һәм фарсы теленнән алынган исемнәр *җәмәгать* сүзе кебек үз чыганак теле кагыйдәсенә буйсынып, төзек яисә ватык күплектә бара: сурәт әҗзаларыны [Бигиев, 1991, б. 223, 238], әкрибасы [Бигиев, 1991, б. 224] төрлү-төрлү әшхас [Бигиев, 1991, б. 235, 245], тарафәиндә [Бигиев, 1991, б. 233], әтрафдан [Бигиев, 1991, б. 236] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» әсәрендә дә (1890) абстракт мәгънәле гарәп-фарсы алынмаларының үз чыганак теле кагыйдәсенә туры китерелеп язылуы шул ук тәртиптә бара: әшхасның әксәре (шәхесләрнең күпчелеге) [Бигиев, 1991, б. 254], бер кечек җәмгыйәт улып, әшйа вә әсбабларны қалдырып [Бигиев, 1991, б. 255] һ.б.

Конкрет мәгънәле исемнәрнең берлеге – аларның берлеген, күплеге билгесез күплеген белдерә: Тәфтишчеләр нумерләргә кердүкләрендән соңра, ... нумерләр сахибе, ... 11 нче нумерәйә керделәр, ... тәрәзәләре икешәр кат... [Бигиев, 1991, б. 222], ... Қазанға мәдрәсәгә уқырга йибәрәмез [Бигиев, 1991, б. 255], Қазанда мәдрәсәдә улып [Бигиев, 1991, б. 256], ... Қазан мәдрәсәләре бөек вә олуғ мәдрәсәләрдер [Бигиев, 1991, б. 256] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, тар контекстта бер үк сүзнең әле берлектә, әле күплектә эзлекле кулланылмавы, беренче төрдәге хикәяләү белән чагыштырганда, әсәрне хикәяләүнең билгеле бер көен-ритмын барлыкка китерә алмый.

Бу романда сөйләнә торган вакыйганың үлем һәм аны тикшерү нигезендә язылуы сәбәпле микъдар саны белән кулланыла торган исемнәрнең активлыгы арта. Алар, гадәттә, берлектә файдаланыла: өч рублә на чай, сигез сәғать илә унике сәғать [Бигиев, 1991, б. 222], йөз мең сум көмеш ақча [Бигиев, 1991, б. 223]. Күплек санда да килергә мөмкин: ничә йөз кешеләр җәмғы улдылар [Бигиев, 1991, б. 236] һ.б.

Күплек төшенчәсе эчтәлегендә микъдар (чама, үлчәм, сан белдерелү) мәгънәсе булган *нәчә (ничә), күп, кач, чук, зиядә, җәмигъ (барлык), җөмлә (барысы), әскәр (күп)* һ.б. төрки-татар һәм гарәп-фарсы алынмалары белән аналитик-синтаксик ысулда белдерелә. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында: күп адәмләр, күп төрле сүзләр, күп хәер доғалар, қач көнләр хыялымда, җәмғ улмыш кешеләр; «Гөнаһе кәбаир» әсәрендә: ...күп шәһәрләрә, нәчә вә нәчә данә вә ғалим мөдәррисләр, нәчә вә нәчә сәнәләрдән бирү, нәчә вә нәчә толлабәләр, нәчә вә нәчә йирләрдә улдылар, хили инғам вә ихсанлар күреп [Бигиев,

1991, б. 257]; «Мавәраэннәһердә...» сәяхәтнамәсендә: қач йөз сәнәләр, бер қач гасыр, бер қач көн соңра, бер қач вәли имеш, мәшһүр пәк чуқ затлар, ничә көнләр күз йәшләре түгеп, ғайәт чуқ фетнәләр пәйда улмыш [Бигиев, 1991, б. 290] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, күплекне белдерү өчен, авторның бер әсәрендә *күп* сүзе, икенче әсәрендә *нәчә*, өченче әсәрендә *кач* сүзе ешрак кабатлана.

З. Бигиевнең романнарында хис-кичерешләр чагыла торган өзекләр булмаганга күрә күплек саны кушымчасының эмоциональ-экспрессив функциясе файдаланылмый диярлек, әмма авторның укучыларына һәм персонажларның берсе икенчесенә хөрмәтләп эндәшкәндә күплек кушымчасын файдалану дәвам ителә. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында: ...ғыйзәтлү Муса әфәнделәренә, ... Сезләрә дә, хөрмәтлү укучыларым, ... Сез газизләрә мәктүб язмадығым бәнем тарафымдан олуғ ғаебдер, ... әхвалемне сезләрә бәян идеп,... [Бигиев, 1991, б. 250] һ.б. Әмма *хәзрәтләре* дигән титулның күплектә бирелүе сакланмый: мөәзин хәзрәтләре [Бигиев, 1991, б. 255], қарт хәзрәт [Бигиев, 1991, б. 256], қарт хәзрәтнең [Бигиев, 1991, б. 257] һ.б.

Р. Фәхретдин әсәрләрендә исем сүз төркеменең сан категориясе белән бәйле мәсьәләләр югарыда искә алынган тәртиптә бара. Гомумҗыймалык төшенчәсен белдерә торган гарәп-фарсы алынмаларының күплеге үз чыганак тел кагыйдәсе буенча «төзек» һәм «ватык» ысулда белдерелә: хисабсыз мәхлуқатның (мәхлукның күплеге) арасында инсанларны башкалардан аерым итмешдер [Фәхретдин, 1899, б. 2]. Шул ук вакытта әлеге сүзләр *-лар/-ләр* кушымчасы да алып кулланыла: мөзәккәрләр илә мөәннәсләрнең (ир илә хатунларның) бер-беренә мәел вә мәхәббәт идеб, Аллаһы Тәгалә хәзрәтләренең… [Фәхретдин, 1899, б. 2] һ.б. «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1898) әсәрендә: ...Хәзердә олуғ бүлемендә рус халықлары тереклек итмәктәдер, дүртенче өлеше әһле исламдыр, мөселманлар җөмләсе сөнни, ... әдәпле ул халық сәвәр, бер груһ халық, җәмғыйәт эчендә улған халықлар, ... пароходта халық күп иде, ... конторада улан халықлар, ... бу күп халықның арасында, ... ошбу күп җәмәғать, ... пароход халқы, ... ғарәп халықлары [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 266, 267, 272, 277] һ.б.

«Әсма, яки Гыйлем вә җәза» (1903) әсәрендә: мөнасыйп мөғалимләр, Қазан вә Қазан этрафында (тарафның күплеге) улан бөек ғалимләрнең, ғыйлемлек хөрмәтене [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 313], мал вә күп әмлак (малның күплеге) сахибе [Татар мәгърифәтчелек...,

1979, б. 314], иске ғасырларны вә иске ғасырның халықларыны, һәр төрле халыққа, бөтен аwыл халқы, халықлар урыннарына кереп ятдықлары соңында, иске дөнья кешеләре [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 317–319] һ.б.

Әсәрләрдә парланып кулланыла торган исемнәрнең икесенең дә берлектә кулланылуы күзәтелә: чапан вә чалма киеп, һөнәр вә мәғрифәт, ғыйлем вә һөнәр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 266], ғаилә вә әдәп җәһәтенчә, ибдәш вә сердәш [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 316], хикәя вә романлар [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 319] һ.б.

Шуның белән бергә, Р. Фәхретдин әсәрләрендә, күплек төшенчәсенең эзлекле рәвештә синтаксик ысул белән белдерелүе дә күзәтелә: ...ничә еллардан бирү, җөмлә кимчелекләрем илә қабул идәрләр, ... чуқ шөкерләр улсын, ... күп халықның арасында, ... күп мәртәбә күрдем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 264], ... күп әмләк сахибе, ... чуқ шөкер, ... җөмлә хатынлар, ... күп әхwәле, ... җөмлә әшйә вә йортлары янып, җөмлә иғтибарлы затлар боны сәвәрләр, җөмлә инсанлар [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 312] һ.б.

Хис-кичерешләрне тасвирларга кирәк булганда, алдагы авторлардагы кебек үк, җөмләләрдә тезелеп кулланыла торган исемнәрнең барысы да күплек санда күрсәтелә: Әгәр дә бу сүзгә җаwап вирүче истанбуллы улса иде, ағызындан баллар, хәлвәләр, шикәрләр түгәр иде, ... бәндә улған дел қарларны эредерлек, тимерләрне йомшартырлық улмай, балаларны юатырлық қадәр дә дәгелдер [Фәхретдин, 1898, б. 37], ...Иске тарихларымызны сөйләдегендә, иске ғасырларны вә иске ғасырның халықларыны тәмам күз уңында китерер иде. Үгезләр йигеб, арбаларның көпчәкләрене (тәкәрмәч) сары май илә майлап сырт өстләрендән йөрүләрене сөйләдеге wақытында, дыңлаучылар кәнделәренең тимер юл, пароход, телеграмм, телефон заманасында идекеләрене онытып, иске дөнйа кешеләре улырлар иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 317]; ...Иң саф күңелле вә иң гүзәл холыклы затларны мәхәббәт әһелләре арасыннан эзләгез! Бер-беренә очрадыклар вакытта йөзләре нурланыр, йөрәкләре селкенер, тезләре тетрәр, җөмлә шатлык вә хәсрәтләре онытылып, ялгыз каршыларында бер-берене күрерләр. Әмма нәкадәр дә саф вә халис мәхәббәтдер! [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 327] һ.б.

Ф. Кәриминең хикәяләрендә гомумҗыйма төшенчәне белдерә торган сүзләр, нигездә, берлек санда кулланылалар: …җәмәғать

арасында [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 233], пристань халкын сәер итәргә [Кәрими, 1996, б. 31], бөтен халык көлеште [Кәрими, 1996, б. 32], ... халык җыелған [Кәрими, 1996, б. 33]. Шул ук вакытта алар күплек санда да очрыйлар: ...шәриғатьләр, иғтикадият, ғамилият [Кәрими, 1996, б. 46], шәриғатькә [Кәрими, 1996, б. 47] һ.б. Әйбер-матдә атамалары *-лар* кушымчасы белән кулланыла башласа, авторның персонажларына карата кире мөнәсәбәте сурәтләнүе аңлашыла: ...читеккә сөрткән майлар халатларға буялып, кешене сасытмыймы икән, дип бер-беребездән сорашабыз [Кәрими, 1996, б. 33]; ...Туй мәҗлесенең казларын вә күзикмәкләрен тәнавел итеп, ... Тарелка-тарелка коймаклар бушады... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 240] һ.б. Шул ук кушымчаның эзлекле файдаланылуы, киресенчә, авторның уңай хич-кичерешләре тасвирлануын да аңлата: ...Ялтырап чыккан кояшның нуры бөтен дөнйаны яктыртып, берничә айлардан бирле үлек хәлендә җансыз булып торған табиғатькә, йәғни ағачларға, суларға, хайваннарға вә инсаннарға йаңадан җан бирмәктә исә дә, эсселеге илә рәхәтсез итәрлек дәрәҗәдә түгел иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 220]; Юлның ике тарафындағы сахралар, хәтфә кебек йәм-йәшел үләннәр вә төрле-төрле ләтыйф (матур) чәчәкләр илә өртелмештер. Һәр нәүғы гүзәл вә ләтыйф күбәләкләр илә төрле-төрле чебеннәр вә кортлар, әрле-бирле очышып, сахраның гүзәллегене арттырмакта иделәр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 229]. Күплек кушымчасы алган исемнәрнең *вә* теркәгече белән тезелеп бирелүе дә күренә. Парланып бирелә торган исемнәрнең икесе дә күплектә булырга мөмкин. Күплек сандагы исемнең *вә* теркәгече *белән* парланган сыйфатлар ярдәмендә анықланып бирелү алымы яратып файдаланыла һәм әсәрнең ритмын хасил итә.

Шуның белән бергә, күплек төшенчәсе аналитик ысул белән белдерелә: күп хикәятләр, күп wакытта [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, 222], күп адәм күреп [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, 225], бик күп бала таwышы, бик күп тирес, ... ничә йөз кешесе, бик чук шартлары, күп wакытта [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 230]. Авторның сәһхатнамәләрендә исә аналитик ысулны барлыкка китерүдә *чук, кач, әксәр* сүзләре активлаша: ... Вә озын сәфәрләр өчен бик чук хәзерлекләр күрмәк лязем килмеш, ... чук ихтыяҗ йукдыр [Кәрими, 1902, б. 2], әксәр сүзләр илә [Кәрими, 1996, б. 156],.бер кач сәнәләрдән, чук wакытымыз [Кәрими, 1996, б. 160], әксәр сүзләре, татарларның әксәре [Кәрими, 1996, б. 161], ... Аурупалылар бер чук тәдбирләр вә чаралар

булмышлар [Кәрими, 1996, б. 311], ... әксәр урамлары таш илә түшәлмеш,..чуқ вә олуғ шәкертләре улан Қышқар... [Кәрими, 1996, б. 314], бер морзадан, бер қач адәмдән [Кәрими, 1996, б. 315], Русийәнең бер чуқ җирләренә, ... бик чуқ ғайрәт вә һиммәтләр илә хисапсыз маллар сарыф иделмеш [Кәрими, 1996, б. 317] һ.б.

Исемнең сан категориясенә караган үзенчәлекләр, сәнгать әсәрләрендәге кебек үк, әдәбият гыйлеме турында языла торган мәкаләләрдә (мәсәлән, Җ. Вәлидинең «Әдәбият барышы» (1912), Г. Сәгъдинең «Әдәбият ысуллары» (1912) һ.б.) күзәтелә.

Татар прозасында хикәяләүнең өченче төре Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал кебек классик әдипләр иҗаты белән башлана. Югарыда әйтеп үтелгәнчә, бу әдипләрнең хикәяләрендә кыскача кереш сүз бирү дәвам ителә. Әлеге очракта әдәби әсәрнең эчтәлеген автор турыдан-туры сөйләп бармый, сүзләр үзләренең бер мәгънәсе белән генә түгел, бәлки күп мәгънәсендә куллана, дигән аңлатма бирелә. Беренче төр, икенче төр һәм өченче төр хикәяләүнең керешләреннән күренгәнчә, әлеге башламнарда һәр чор өчен актуаль булып санала торган билгеле бер филологик мәсьәләнең күтәрелүе аңлашыла.

Ялгызлык исемнәре дигәндә, беренче чиратта, әлбәттә, персонажларның исем-атамалары истә тотыла. Аерым авторларда, алдагы чорлардан килә торган традиция дәвам ителеп, үзәк геройның исеме әсәрнең атамасы булып куела: «Зөләйха», «Хәят» һ.б. Әмма бу алым яңартыла, әсәрдә сурәтләнә торган хәлләрнең аерым шәхескә генә түгел, күпчелеккә караган булуы истә тотылып, әсәрнең исеме итеп, персонажның профессиясе (кәләпүшче кыз, теләнче кызы, сөннәтче бабай, мулла бабай), гаилә хәле (бай углы, кияү, мәдрәсә җимеше, остазбикә һ.б.) сайлана. Шул рәвешле аерым шәхес белән бәйле хәлләр күпчелеккә каратыла. Шуның белән бергә төп мәгънәсе әсәрнең идеясен белдерү өчен махсус катлауландырылган аерым бер сүз, сүзтезмәнең исеме итеп бирелүе гамәлгә куела: «Уяну», «Буранда», «Яз башы», «Диңгездә» һ.б.

Предметлык категориясе нигезендә берләшә торган башка лексик-семантик төркемчәләрнең кулланылышындагы язма традициянең төрле авторда төрле дәрәҗәдә эволюция кичерүе күренә.

Хикәяләүнең өченче төрендә язылган чәчмә әсәрләрдә дә традиция булып килә торган абстракт мәгънәле алынмаларны куллану дәвам ителә. Күпчелеге җыйма төшенчәне белдерә торган бу исемнәр

конкрет мәгънәле исемнәр кебек үк һәм берлек, һәм күплек санда файдаланыла: ...баламны ничек булса да ғыйлем юлына кертеп, дөнйамызға, ахирәтемезгә файдалы ғыйлемләр насыйп әйлә, ... мулла булмаған кешегә дә ғыйлем фарыз [Исхакый, 1998, б. 31], ...алар ғыйлемнең қадерен белә торган кешеләр [Исхакый, 1998, б. 33], ғыйлемгә қарамый [Исхакый, 1998, б. 34], ...дин юлында, милләт юлында, мәмләкәтләр нинди икәнене белермен [Исхакый, 1998, б. 37] һ.б.

Җыймалыкны белдерә торган гарәп-фарсы алынмалары тагын *-лар/-ләр* кушымчасы алып та кулланыла: әбәди мәсғудиятләр (мәңгелек бәхетләр) ирешмәкдер [Исхакый, 1998, б. 32]. Гарәп теленең «ватык» күплектәге исеме татарча варианты белән бергә кулланыла: әшйалар-әйберләремне хәзерләрмен [Исхакый, 1998, б. 38] һ.б. Г. Исхакыйның беренче әсәрләрендә үк хикәяләүнең беренче һәм икенче төрләрендә кешеләрнең тупланмасы дигән мәгънә *халық – халықлар – чуқ халык* дип кабатлана торган шәкелнең күплек сандагы бирелеше пассивлаша. Әлеге сүз җанлы сөйләмдәге кебек берлек санда ешрак кабатлана: ...безнең надан халық [Исхакый, 1998, б. 32], безнең халық [Исхакый, 1998, б. 34], ... безнең халықта [Исхакый, 1998, б. 35] һ.б.

Шуның белән бергә, «Тәгаллемдә...» хикәясенең беренче җөмләсеннән күренгәнчә, хис-кичерешләргә төрелә торган өзекләрдә санала торган конкрет мәгънәле исемнәр дә (агачлар, яфраклар, үләннәр һ.б.) санала алмый торган абстракт мәгънәле исемнәр дә (хәсрәтләр, гомерләр, күңелләр, кайгылар, күз яшьләре) һәммәсе күплек санда кулланыла. Шул рәвешле әдип белән персонажга караган уртак хис-кичерешләр тасвирлана. Авторның мөмкин булган дәрәҗәдә төрки-татар чыгышлы абстракт мәгънәле исемнәрне кулланырга тырышуы күренә: ике мәртәбә кабатлана торган (өченчесе – фигыль) абстракт мәгънәле алынма *хәсрәт* сүзе белән рәттән, төрки-татарның үз сүзләре саналган *күңелләремә кайгылар* шәкеле ике мәртәбә кабатланып бирелә. Әдипнең башка проза һәм драма әсәрләрендә дә күплек санының эмоциональ-экспрессия белдерә алу вазифасы эзлекле рәвештә файдаланыла: Кәримә күзләре йәшле, күңелләре қайғылы көенчә бөтен кичне үткәрде. Ғомерендә күргән рәхәтләрен, михнәтләрен уйлап қарағач, күңелләре, гүя, бөтен дөнйаның хәсрәтләренең, табиғатьнең зәһәрләрен тәҗрибә қыла торган урыны кебек булған иде [Исхакый, 1998, б. 67] һ.б. «Үземез сөйли торган телдә язарга тиеш димен», – дип иҗат эшенә тотынган Г. Исхакый гомумсөйләм

элементларын, шул исәптән күплек саны кушымчасын да, бик яратып, аның барлык хасиятләрен, мәгънәләрен белеп файдалана. Бу очракта инде *-лар/-ләр* кушымчасының лексик-семантик төркемчәләрнең мәгънәсен төрле төсмер белән үзгәртүе вазифасыннан башка, аерым әсәр эчтәлегендә тасвирлана торган күренешләрне хис-кичерешләр белән баетып, эмоциональ-экспрессив функция үтәү өчен дә файдаланылуы аңлашыла.

Әйбер-матдә белдерә торган исемнәрнең берлектә дә, күплектә дә кабатлануы классик әдипләр иҗатында да яратып кулланыла: Андағы қаймақлар, майларны, тозлы ит, тозлы қазларны күздән кичерде, бәлешләргә табалар йитәрлек булмаса да… [Исхакый, 1999, б. 188], …эллә ниқадәр сумсалар, қодагыйға дип, зур-зур күмәчләр, һәйбәт бәлешләр, пешкән очалар бирелде [Исхакый, 1999, б. 195], ...Ашлар, сыйлар – һәммәсе муллаларча үтте [Исхакый, 1999, б. 198], ...Килен иң әүwәл сары майға ғына қоймақны салды, ул қызарып өсте килгәнчә пәрәмәчләрне тутырып… [Исхакый, 1999, б. 202] һ.б. Г. Исхакыйның әсәрләрендә күплек идеясе күплек сандагы исемне аныклап килгән *мең* сүзе белән дә белдерелә: Аллаһы тәгалә безне тәрбияңезгә меңмең рәхмәтләр күндерсен [Исхакый, 1999, б. 44], ...мең төрле уйлар уйлап [Исхакый, 1999, 45]; ...Мең-мең шөкерләр булсын, әфьюнлы башлы муллалар ахирәткә юнәлә башладылар [Исхакый, 1999, б. 179] һ.б.

Шуның белән бергә, мисаллардан күренгәнчә, Г. Исхакыйның сәнгатьле прозасында эзлекле рәвештә тезелеп килә торган тиңдәш кисәкләр, мәгърифәтче әдипләр иҗатында актив булган *вә* теркәгеченнән башка гына кулланылганга, парланып тиңдәшләнү югала, хикәяләүнең интонациясе үзгәртелә.

Шулай итеп, татар прозасында өченче төр хикәяләүне башлап җибәргән Г. Исхакыйның беренче хикәяләрендә *исем* сүз төркеменең сан категориясен куллануда кайбер үзгәрешләр дә күзәтелә: җыймалыкны белдерә торган сүзләрнең күплек кушымчасы белән кулланылу шәкеле пассивлаша; җыймалыкны белдерә торган кайбер алынмалар татар теленең үз абстракт мәгънәдәге сүзләре белән алмаштырыла, ягъни җанлы сөйләмә формалар әдәбиләштерелә; гомум-җыйма мәгънәне белдерә торган исемнәр татар теленең сүзләре белән тәгаенләнә; *-лар/-ләр* кушымчасы барлык семантик төркемнәргә кушылып, билгесез күплекне, тупланганлыкны, төрлелекне һ.б. мәгънә төсмерләрен белдерә, рәттән тезелеп кулланылганда, автор белән персонажның берлектәге хис-кичерешләрен тасвир итү чарасына әверелә.

Г. Исхакыйның башка әсәрләрендә һәм бүтән әдипләр иҗатында әлеге үзенчәлекләр тагын да активлаша.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә җыймалыкны белдерә торган абстракт мәгънәле алынма сүзләр, асылда, чыганак телдәге шәкеле белән файдаланыла: халық та җыелды, ... гомум җәмәғать «амин»дип қычқыра, ... халық та түгәрәкләнеп утырдылар һ.б. Төрки-татар телендәге абстракт мәгънәле сүзләр күплек санда кулланылганда, аларның мәгънәсе конкретлаша: күргән қыенлықларыны вә ағыруларыны бетерү өчен... [Ибраһимов, 1974, б. 411–412] һ.б.

Конкрет мәгънәле сүзләр *-лар/-ләр* кушымчасы алганда, аларның күплектә булуы аңлашыла: безем шәкертләр, ... шәкертләрнең кайсы бик шат …, чалмалы хәерчеләр… [Ибраһимов, 1974, б. 414]. Аерым өзекләрдәге җөмләләрдә төрле семантик төркемдәге сүзләр рәттән *-лар/-ләр* кушымчасы белән кулланыла башлагач, хис-кичерешләрне тасвир итү вазифасы сиземләнә: қояшлы көнләр, яшел хәтфә кеби үләнләр, ағач яфрақлары, әллә нинди қайғыларыны да тарата торган сандуғач вә турғай таwышлары бетде, һәр көн қар вә яғмурлар яwыб, бар ғомерләрене урамда уйнаб үткәргән балаларға уйнарға җайсызлый башлады [Ибраһимов, 1974, б. 399] һ.б. *Вә* теркәгече белән теркәлгән ике сүзнең соңгысының күплектә кулланылу традициясе саклана: сандуғач вә турғай таwышлары, қар вә яғмурлар явып [Ибраһимов, 1974, б. 399] һ.б. Әмма вариантлылык та күзәтелә: күмер вә ақбур берлән [Ибраһимов, 1974, б. 400], йортлары вә адәмләре [Ибраһимов, 1974, б. 401], хәлфәләр вә хәлфәләрне ашата торған [Ибраһимов, 1974, б. 403] һ.б.

Төрки-татар теле өчен әдәби норма булган күплектәге һәм гарәп-фарсы телендә әдәби булган күплектәге исемнәрнең кулланылышында (һәр өч төрле хикәяләү ысулында да) функциональ-стилистик вариантлылык күзәтелә, ягъни алар төрле текстта төрле дәрәҗәдә кабатлана, төрле микъдарда сайланып алына. К. Насыйриның фәнни хезмәтләрендә, сәнгатьле прозасына караганда, алынма сүзләр, шул исәптән күплек сандагы исемнәр дә күбрәк кулланыла. Шушы ук күренеш З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими иҗатларында чагылыш таба. З. Бигиевның «Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)», Ф. Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе» һәм «Кырымга сәяхәт» һәм шулай ук фәнни хезмәтләрендә, Р. Фәхретдиннең «Асар» һәм башка фәнни хезмәтләрендә алынма сүзләр, шул исәптән күплек сандагы исемнәр дә күбрәк кулланыла [Бәширова, 1992,

б. 141–143]. Гарәп һәм фарсы алынмаларының ешрак кабатлануы М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» хикәясендә, Г. Камал белән Г. Исхакыйның кайбер әсәрләре алдында бирелә торган кереш сүзләрендә, Ф. Әмирханның беренче хатларында, Г. Ибраһимов белән Г. Тукайның башлангыч чор иҗатында күзәтелә, димәк, боларның барысында да күплек сандагы гарәп-фарсы алынмалары да махсус рәвештә сайланып файдаланыла.

Абстракт, конкрет, җыйма, әйбер-матдә мәгънәле һәм сан белән ачыкланган исемнәрнең күплек формасында белдерелүе, башка стильләр белән чагыштырганда, матур әдәбият стиленең төрле жанрында язылган текстларда, хикәяләүдә билгеле бер ритм хасил итеп, хис-кичерешләрне тасвирлау вазифасын үтәвендә чагыла.

Күплек кушымчасының язуда чагылышынада ныклы система күзәтелми, графо-орфографик вариантлылык хасил була: حانه لرى – ханәләре, باشلرى – башлары, حالقلرى – халыкълары, شهرلره – шәһәрләрә, سرايلارى – сарайлары, آدملر – адәмләр [Акъегет, 1886, б. 2].

М. Акъегет, З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими һ.б. мәгърифәтче әдипләрнең төрле жанр-стильдәге хезмәтләрендә һәм каты сүзләрдә, һәм йомшак сүзләрдә эзлекле булып әлифсез күплек кушымчасының кулланылуы күзәтелә. Шушы ук тәртип Г. Исхакый, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал һ.б. классик әдипләрнең башлангыч чор иҗатларында дәвам ителә.

Күплек санның хәзерге татар телендә әдәби норма буларак кулланыла торган вариантлары Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» дигән хезмәтендә бирелә: «...Күплек санында исә беренче рәт исем төрлекләре *-лар, -ләр* кушылып төрләнә. Бу төрлек татар телендә, нигез исемнәрнең нинди авазга туктавына карап, ике төрле була: 1) борын авазларына беткән исемнәрдә *-нар, -нә*р төрендә: таңнар, көннәр, килгәннәр кебек; 2) башка авазларга беткән исемнәргә кушылганда, *-лар, -ләр* төрендә килә: кешеләр, кошлар, кумәчләр, балалар кебек» [Алпаров, 2008, б 101]. Үзеннән-үзе аңлашылганча, гарәп графикасындыгы текстны кириллицага күчергән вакытта, күплек сандагы исем һәм фигыльләрнең һ.б.ның үз чоры вариантлылыгына игътибар ителми, хәзерге татар әдәби нормаларында бирелә.

*Кыскача нәтиҗәләр.* Өйрәнелә торган чорда иҗат ителгән әсәрләрдә, берлек һәм күплек мәгънәсе, алдагы чорлардан килә торган традиция сакланганы хәлдә, ике телгә хас булган әдәби норма күрсәткечләре белән тәгъбир ителә. Беренчесе – төрки-татар теле өчен

әдәби булганы: берлек саны – нуль форма, күплек саны *-лар/-ләр* кушымчасы белән белдерелә. Икенчесе – гарәп һәм фарсы теле өчен әдәби булганы: берлек саны – нуль форма, икелек саны – *-ан, -әйен,* «бөтен» күплек *-ат, -ун, -ин, -ийат (-ият)* аффикслары белән, «ватык» күплек саны кушымчасыз, сүзне ватып, аның сузыкларын алмаштыру ярдәмендә ясала, фарсы алынмаларында *-ан* кушымчасы белән белдерелә.

Параллель бара торган әлеге ике әдәби норманың 1) графо-орфографик, 2) морфологик, 3) синтаксик нигездә карарга мөмкин булган әдәби норма вариантлары күзәтелә.

Графо-орфографик вариант дигәндә, күплек кушымчасының язуда ничек итеп күрсәтелүе истә тотыла. XIX йөзнең беренче һәм икенче яртысында иҗат ителгән поэзия әсәрләрендә, сүз тамырында нинди сузык әйтелүгә карамастан, күплек кушымчасы әлифле, яисә әлифсез булып языла. Ә. Каргалый иҗатында күплек сан кушымчасының әлифле варианты кулланылса (لار-), башка авторларда, асылда, әлифсез вариантка (لر-) өстенлек бирелә. К. Насыйриның «Әнмүзәҗ» хезмәтендә күплек кушымчасының сүз тамырында ишетелә торган сузыкка ярашып язылырга тиешлеге кагыйдә булып күтәрелсә дә, аның төрлечә бирелүе дәвам итеlә. XX гасыр башында, язма тел хакындагы фикер алышуларда, әлеге мәсьәләгә махсус игътибар бирелә. *-лар* кушымчасының калын һәм нечкә сузык авазга ярашып язылырга тиешлеге кабатлана. Г. Ибраһимов хезмәтендә күплек кушымчасы әлифсез вариантта бер генә төрле итеп язылырга тиеш дип белдерелә.

Морфологик вариант дигәндә, түбәндәге мәсьәләләр истә тотыла: а) гомумкатегориаль предметлык нигезендә берләшә торган ялгызлык, күмәклек, санала торган конкрет һәм санала алмый торган абстракт, җыйма, әйбер-матдәгә караган лексик-семантик төркемчәләренең парлы рәвештә, яисә микъдар саны белән килгәндә берлек санда да, күплек санда да кулланыла алуы; ә) *-ат, -ин* күрсәткечле һәм «ватык» күплектәге гарәп-фарсы һәм *-ан* кушымчалы фарсы алынмаларының һәм үз телендәгечә, һәм икеләтелгән күплектә, ягъни *-лар* кушымчасы белән дә килә алуы; б) *-лар* аффиксының билгесез күплекне белдерүе белән бергә, тагын абстракт мәгънәле исемнәрдә конкретлык, матдә исемнәрендә сорт-төрлелек, җыйма исемнәрдә төрле урынга таралганлык, ялгызлык исемнәрендә гаилә-туганлык, даирә-фикердәшлек кебек мәгънә төсмерләре өсти алуы белән бергә, эмоциональ-экспрессив хис-кичерешләрне аңлата алуы. Хикәяләүнең беренче һәм икенче

төрендә иҗат ителгән мәгърифәтчелек әдәбияты әсәрләрендә аның бу мөмкинлеге авторның укучысына һәм персонажларның үзара хөрмәтләп эндәшү алымы буларак та файдаланыла. Классик әдипләр иҗатында ул аңлы рәвештә аерым образларны тасвир итү чарасына әверелдерелә. Үзеннән-үзе аңлашылганча, фәнни хезмәтләрдә һәм башка утилитар стильләрдә күплек кушымчасының бу вазифасы шактый йомшара яки бөтенләй күзәтелми.

Синтаксик вариант дигәндә, берлек һәм күплек идеясенең аналитик (синтаксик сүзтезмә) ысул белән белдерелә алуы истә тотыла. Аналитик ысулдагы берлек мәгънәсе берлектәге исем *бер* саны, *ул, бу* алмашлыклары, берлек сандагы III зат тартым белән бергә файдаланылганда белдерелә; бу очракта *бер* саны билгесезлекне дә аңлатырга мөмкин. Күплек мәгънәсе морфологик күрсәткечтән башка тагын күплек, бергәлек, җыймалык төшенчәләрен белдерә торган сүзләр, яисә аларның кабатлануы белән дә тәгъбир ителә. Хәзерге әдәби тел белән чагыштырганда, бу мәгънәне алып килә торган татар теле сүзләреннән башка, борынгы төрки, гарәп һәм фарсы алынмаларының да кулланыла алуы сәбәпле, сан ягыннан күбрәк файдаланылуы күзәтелә.

Сан категориясендә әдәби норма һәм норма вариантлылыгын тәшкил итә торган әлеге парадигмалардан теге яки бу стиль, яисә аның берәр жанр-төренең таләбе белән махсус рәвештә берсенең сайланып кулланылуы, функциональ-стилистик вариантлылыкны барлыкка китерүе ачык күренә.

*Тартым категориясе.* Грамматик категория буларак мәгънәсе буенча предметның нинди дә булса затка, яки икенче предметка караганлыгын белдерә торган тартым категориясе беренче, икенче, өченче затка караган берлек һәм күплек кушымчалары-формаларында чагылыш таба [Татар грамматикасы, 2002, т. II, б. 40].

Гомумтюркологик хезмәтләрдән аңлашылганча, исемнәргә хас булган тартым категориясенең барлык төрки телләрдә дә грамматик категория буларак морфологик, морфологик-синтаксик һәм синтаксик ысуллар белән белдерелүе борынгы язма чыганакларда ук файдаланылган [СИГТЯ, 1988, с. 22–23]. «Языки мира: Тюркские языки» дигән энциклопедик хезмәттә (1997) борынгы һәм хәзерге телләрнең барысында да тартым категориясенең чагылышы күрсәтелә һәм анализлана. Татар телен тарихи планда өйрәнеп язылган хезмәтләрдә, тартым ысулларының иске (борынгы) истәлекләрдән үк килүе һәм аларны аморф формалы (түрк бәгләр), ярым тартымлы (түрк будун

аты), тулы тартымлы (түрк будуныг аты) дип атарга мөмкин булуына игътибар ителә [Җәләй, 2000, б. 34–35].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында язылган татар теленең сарыф вә нәхү дип атала торган грамматика дәреслекләрендә тартым кушымчалары алмашлыкларның бер төре итеп карала [Фәизхан, 1887, б. 14–16]. К. Насыйриның «Әнмүзәҗ» хезмәтендә дә тартым кушымчалары «Исме замирлар» бүлегендә карала [Насыйри, 1895, б. 12–14].

Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) дигән хезмәтенә кадәр язылган күп кенә дәреслекләрдә дә тартым кушымчасын алмашлыкның бер төре дип аңлату дәвам ителә, фәкать Ә.-Һ. Максуди гына үзенең «Төрки сарфы» (1910) китабында әлеге төрдәге күрсәткечләрне исемнәргә мөнәсәбәттә карый [Татар грамматикасы, 2002, т. II, б. 39]. Г. Алпаров исемнәрнең әлеге күрсәткечләрне алуларын «япсару белән төрләнеш» дип атый һәм, үзеннән алда язылган грамматикалардан аермалы буларак, кушымчаларны татар халкының сөйләмә нормасында бирә: күзебез, балабыз, күзегез, балагыз һ.б. Шул ук вакытта түбәндәге искәрмәне китерә: «Башка төрек телләрендә дә исемнәрнең япсару төрлекләре бер төсле диярлек. Тик татар, башкорт телләреннән башкаларда *-быз, -без, -гыз, -гез* төрлекләре *-мыз, -мез, -ңыз, -ңез* төрендә әйтелә» [Алпаров, 2008, б. 101–102].

В. Хангилдинның хезмәтендә «... предметның бер-бер затка (1, 2, III затка) нисбәт ителүен белдерә торган грамматик категорияне «тартым» дип атауга караганда, нисбәт (категория принадлежности) дип атау дөресрәк булыр иде», – дип аңлатыла [Хангилдин, 1954, б. 66]. Хәзерге татар телендә тартым категориясе синтетик, аналитик, аналитик-синтетик ысулларда белдерелә дип өйрәтелә [Татар грамматикасы, 2002, т. II, б. 41]. Исемнәрнең бу ысуллар белән тартымлануын Л. Җәләй төрки изафә дип гомумиләштерә. Барлык хезмәтләрдә дә өченче зат тартымлы исем, икенче исем белән ачыкланып, күп төрле мөнәсәбәтләрне дә белдерелә ала, дигән фикер әйтелә [Хангилдин, 1954, б. 68; Җәләй, 2000, б. 34; Татар грамматикасы, 2002, т. II, б. 43–44]. Хәзерге татар әдәби телендә тартым категориясенең форма һәм мәгънәләре, ясалыш калыбы, килешләр белән булган мөнәсәбәте катгый ачыкланган [Татар грамматикасы, 2002, т. II, б. 39–45; Хисамова, 2006, б. 100–107].

Исем сүз төркеменә хас булган әлеге грамматик категория XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында язылган текстларда да, нигездә, шушы низамда бара. I, II, III затка караган тартым мәгънәсе синтетик

һәм аналитик-синтетик ысулларда чагылыш таба, I һәм II зат тартымы тагын аналитик ысул белән дә белдерелә.

Иске татар телендә язылган истәлекләрне тикшерүче галимнәрнең барысы да тартым категориясен өйрәнә. Барлык хезмәтләрдә дә һәр өч затка караган тартымның берлек һәм күплек санда була алуын белдерә торган кушымчалары күрсәтелә, тартымның төрле ысулларда һәм ике исемнең изафә тәртибендә затның яисә предметларның үзара нисбәтен белдерә алуына игътибар ителә. Тик бу хезмәтләрнең күбесендә исем категориясе күрсәткечләренең сүз тамыры (нигезенә) кушылу тәртибе, ягъни башта сан, аннан тартым, аннан соң килеш күрсәткечләре килүе исәпкә алынмый.

XIX гасырның беренче һәм икенче яртысында иҗат итүче Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки, Г. Чокрый һ.б. шагыйрьләр үзләренең әсәрләрен төрки телнең абруйлы, ягъни гарәп һәм фарсы алынмалары белән туендырылган юнәлешендә укымышлы кешеләргә багышлап язалар. Аларның әсәрләрендә тартым мәгънәсенең, төрки-татар теленә хас булган ысулда күрсәтелүе белән бергә, гарәп-фарсы телендәге сыйфатлау һәм изафә тәркибе (тезмәләре) белән бирелешенең дә эзлекле баруы күзәтелә. Әлеге мөмкинлекне төрле автор үзенең максатына ярашлы итеп, төрлечә файдалана ала.

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви-әс-Сәгыйди» (1845, 1889) әсәрендә тартым мәгънәсе төрки-татар теленә хас булган түбәндәге ысуллар белән белдерелә: I зат тартымының берлектәге һәм күплектәге синтетик төре: әлемдә, қальбеме [Каргалый, 1889, б. 2], хәлемез, күземез, йөземез [Каргалый, 1889, б. 3], аяғым, ашымыз, җөмләмез, иманымыз, хәлемез, башым, нәфсемез [Каргалый, 1889, б. 4] һ.б.; I зат тартымының берлектәге һәм күплектәге аналитик-синтетик төре: башым өстендә, нәфсемез арзусыны [Каргалый, 1889, б. 4], кәндү сачемлә [Каргалый, 1889, б. 7] һ.б.; II зат тартымының синтетик төре: әлеңдә, бер илкеңә [Каргалый, 1889, б. 2], тәдбиреңъ [Каргалый, 1889, б. 4], куәтеңе, хәзрәтеңе [Каргалый, 1889, б. 7] һ.б.

Тартымлы исемнәрнең баш килештә генә түгел, башка килешләрдә кулланылуы да күзәтелә: берлекеңнең [Каргалый, 1889, б. 4], бер илкеңә, ошбу сүзләре (сүзләрне), қальбеме (қальбемне), таптыгымызы [Каргалый, 1889, б. 4], әлеңдә, әлемдә, әлендә [Каргалый, 1889, б. 2, 5] һ.б. Әлеге мәсьәләләр килеш категориясендә тикшереләчәк.

Синтетик төрдәге III зат тартымлы исемнәр өйрәнелә торган чорда да хәзерге татар әдәби телендәге кебек *-ы, -сы, -лары* кушымчала-

рын алалар, әмма сузык авазга бәйле булган вариантлылык күзәтелми, транскрипцияләгәндә генә килеп чыга. III зат тартымлы исемнең бу әсәрдә баш килештәге икенче исем белән ачыкланып килү очрагы (аналитик ысул – икенче төр изафә) еш кабатлана: тәсбих рәсмене, Аллаһ исемене, дөнья кәсрәте (муллыгы), дөнья дәүләте (байлыгы) [Каргалый, 1889, б. 2], дин сәрвәре (дин башлыгы) [Каргалый, 1889, б. 4], Хак рәхмәтендин, Сәфиулла бәхете [Каргалый, 1889, б. 6] һ.б. Бу форманың күплек сандагы исемгә караган берлек сандагы тартымлы исем рәвешендә файдаланылуы күзәтелә: ирәнләр таҗы [Каргалый, 1889, б. 2], мөхибләр намыны, әнбияләр сөннәте [Каргалый, 1889, б. 3] һ.б.

III затка караган тартымлы исемнең, иялек килешендәге күрсәтү алмашлыгы яисә икенче исем (аналитик ысул – өченче төр изафә) белән кулланылуы да очрый: боның тәзвиренең (алдавының) [Каргалый, 1889, б. 5], Хабибең өммәте, кәримнең сөннәте [Каргалый, 1889, б. 4], рәсүлең сөннәте, җиһанның җаһ малы [Каргалый, 1889, б. 5], Сөләйманның тәхете [Каргалый, 1889, 1889, б. 6] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, тартым мәгънәсе төрки-татар теленә хас булган ысулда белдерелгәндә дә, исемнәрнең барысы да гарәп һәм фарсы алынмалары белән бирелә.

Шуның белән бергә, тартым мәгънәсе бу әсәрдә эзлекле рәвештә гарәп-фарсы телендәге сыйфатлау һәм изафә тәркибе (тезмәләре) белән дә белдерелә: сөруре әяле (кешеләрнең шатлыгы), шәйхе җиһан (галәм юлбашчысы) [Каргалый, 1889, б. 2], тохмы карбыз (карбыз төше), инна Рабб-ел галәмин (галәмнәрнең Алласы), дәүре әсхабы (дәвер хуҗалары) [Каргалый, 1889, б. 3], әҗре гыйзам (олылыкның әҗере), рәхмәт-әл-галәмин (галәмнәрнең тынычлыгы), хәшр-ү-нары (туплану уты-газабы), ихване дин(дин кардәше), шәреге дин (дини шәригать] [Каргалый, 1889, б. 4] [Каргалый, 1889, б. 12] һ.б. Аңлашылганча, тартым төшенчәсенең гарәп-фарсы телендәге сыйфатлау һәм изафә ысулы белән бирелеше сан ягыннан күбрәк очрый.

Һ. Салиховның «Китабы мәҗмәгыл адәб» әсәрендә төрки-татар теленә хас булган түбәндәге ысуллар файдаланыла: I зат тартымының берлек һәм күплектәге синтетик төре: تلمد ه – телемдә [Салихов, 1856, б. 2], وجودمدر – wөҗүдемдер, نفسم – нәфесем, يوزمنى – йөземне [Салихов, 1856, б. 6], طشم – тышым, اجم – эчем, اشم – эшем, خوشم – хушым, باشم – башым, تلم – телем, سوزومى – сүземи [Салихов, 1856, б. 7], қалбемездә, сәрмәям [Салихов, 1856, б. 3], اعمالم – әғмәлем [Салихов, 1856, б. 4] һ.б.; аналитик-синтетик төре: بنم اوستةمد ه – бәнем өстемдә [Салихов, 1856, б. 3], عمرم مايه سينه – ғомрем маясына [Салихов, 1856, б. 4] һ.б. Мисаллардан

күренгәнчә, Аллаһы Тәгаләгә ялвару-үтенү авторның үз исеменнән барганга күрә, I зат тартымлы исемнәре күбрәк кулланылган.

II зат тартымының синтетик төрен куллану да, асылда, Аллаһы Тәгалә исеменә мөнәсәбәттә дәвам итеlә: رزقنك – ризыкың, اسمنكاه – исмеңә, رحمتنك –рәхмәтең, عطانك ايله نوالنك – ғатаң илә нәвәлең (бүләгең), سوينكا – сәүеңә (яратуыңа), توفيقنك – тәүфикың [Салихов, 1856, б. 3]. Икенче затның аналитик-синтетик ысулы да шул ук юнәлештә бара: سننك اسمك – сәнең исемең [Салихов, 1856, б. 2], سننك فضلنك – сәнең фазылың [Салихов, 1856, б. 5],

III зат тартымының синтетик төре: көтеп торды йиирендә, йулдашы, саг-сулына, йулдашының йөзене [Салихов, 1900, б. 15] һ.б.

III затка караган тартымның аналитик төре (икенче төр изафә): جماعت يوليدين – җәмәғать йулыдин [Салихов, 1856, б. 3], شريعت حكميده – шәриғать хөкемидә, جهنم اودينه – җәһәннәм удына, عاجزلر پناذى – ғаҗизләр пәнаһы (көчсезләр сакчысы) [Салихов, 1856, б. 5] һ.б.; аналитик-синтетик төре (өченче төр изафә):حب نك كونكلد ه – Хәбибнең күңледә, عالمنك خداسى – ғаләмнең Ходасы [Салихов, 1856, б. 2], نهنك آغزينه – нәһнең агызы [Салихов, 1856, б. 4], جهاننك اولينه آخرينه – җиһанның әүwәленә ахырына [Салихов, 1856, б. 5] һ.б.

Тартым мәгънәсенең гарәп-фарсы телендәге сыйфатлау һәм изафә тәркибе (тезмәләре) белән белдерелүе: جمله جنات نعيمه – җөмлә җәннәт нәгыймә (барлык җәннәт нигъмәтләре) [1856, б. 2], صراط مستقيمه – сыйрате мөстәкыймә (туры йулга), جناب رحمتنكدين – җәнәб рәхмәтендин [1856, б. 3] һ.б.

Ш. Зәки шигырьләрендә тартым категориясенең кулланылышы А. Йосыпов хезмәтендә җентекләп тикшерелә [Юсупов, 2006, с. 15–27]. Бу урында кайсы тартым ысулының күбрәк файдаланылуына игътибар итәбез.

Әдәбиятчы галим М. Гайнетдинов белдергәнчә, «...Ш. Зәкидә шигъри сөйләм... “бән” (мин) дигән сүздән башлана. Шигырьдә шул «мин»нең, аерым шәхеснең, уй-кичерешләре, дәрт-карашлары һәм хиссият дөньясы гәүдәләндерелә» [Шәмсетдин Зәки, 2002, б. 10]. Авторның «И дәрига...!» дип башланган шигыре менә шундый әсәрләренең берсе булганга, лирик образның рухи халәтен сурәтләү өчен, I затка караган тартымлы исемнәр, кулай чара буларак, шигырнең һәр юлында төрле ысул – бәйләнешләр белән эзлекле рәвештә кабатланып файдаланыла: а) синтетик ысул белән: طاقت صبرم قرارم – тәкать сабрым карарым; اختيارم – ихтиярым, جانمه – җаныма, دل آرام – диларам,

كوكلمد ه – күңлемдә, افتكارم – ифтикарем (мохтаҗлыгым), المتى – әлемне, اقتدارم – иктидарым, اميدم – өмидем, غمكسارم – ғамькөсәрем (якын дустым), كوكليمه – күңлемә, انتظارم – интизәрем (зарыгуым); متاعم – мәтагым (кыйбатлы нәрсәләрем), اعتبارم و التفات – илтифат вә иғтибарым, ناموس و غاريم – намус вә ғарем һ.б.; ә) аналитик-синтетик ысулда: وجودم كيمه سى – вөҗүдем көймәсе, نفسم آفتندن – нәфсем афәтендин; б) гарәп-фарсы телендәге сыйфатлау һәм изафә тәркибе (тезмәләре) белән белдерелә: راخت پارم – рахт парәм һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, гарәп һәм фарсы алынмалары белән бирелә торган исемнәрнең, синтетик ысулдагы I зат тартым кушымчасы белән кулланылуы аңлашыла.

Ш. Зәки «Эстәсәм галәмдә...» дип башлана торган шигырендә укучысына «сән» «дустларым» дип эндәшеп, «хәерле эшләрдә тапкыр-тәвәккәл булырга чакыра» [Зәки, 2002, б. 12]. Бу үзенчәлек тартымлы исемнәрнең кулланылышына тәэсир итә, сурәтләү чарасы саналган аналитик-синтетик төрдәге ысул уңай булып чыга: сәнең астыңда, йирнең хәдден, аула күңелең шәярине (данын), җиһанның шәяринең базарының сәүдәсе күб (җиһан данының алыш-биреше күп) һ.б. [Юсупов, 2006, б. 188]. Шулай итеп, шигъри әсәрнең кайсы затка каратып язылуына бәйле рәвештә, тартымлы исемнең аерым бер ысулы сурәтләү чарасы буларак сайланып файдаланыла.

Абруйлы төркидә язылган беренче поэмаларыннан аермалы буларак, Кандалыйның «...мәхәббәт дигән гаҗәп хикмәтле, серле һәм олы күренешнең әдәби фикер урталыгына төп әдәби герой сыйфатында куя һәм соклангыч итеп гәүдәләндерә алуыннан гыйбарәт» [Кандалый, 1988, б. 48] булган шигырьләре, поэмалары халыкчан төркидә иҗат ителә. Сөекле абыстайларга «бән/мән» исеменнән мөрәҗәгать итеп язылган әсәрләрдә тел-сурәтләү чаралары шушы максаттан сайлана һәм кулланыла. Үзенән-үзе аңлашылганча, тартымлы исемнәрнең I һәм II затка караган синтетик төренең эзлекле файдаланылуы күзәтелә. Әлеге тезисны раслау өчен, бер үк шигырьләрнең һәр дүрт юлыннан берничә мисал китерү дә җитә: каләмем – бәғрем – йөзем [Кандалый, 1988, б. 73], хәлемне – малымны – алдымны [Кандалый, 1988, б. 74], сүзләрем – хәлләрем – кулларым, зиһеннәрем таралғандыр, ғазиз башым яралғандыр [б. 78], бәғрем – кадрем – сабрым, бәғрем – һушым – ғомрем [Кандалый, 1988, б. 79] һ.б. Авторның аерым шигырьләрендә аналитик-синтетик ысулындагы тартымлы исемнәрнең кулланылуы да күренә: бәнем ғомрем [Кандалый, 1988,

б. 79], безең илнең [Кандалый, 1988, б. 80], безем йирдә [Кандалый, 1988, б. 84] һ.б. Исемнәрнең күбесенең сөйләм телендә һәм авыз иҗатында кулланыла торган сүзләр булуы аңлашыла. III зат тартымлы исемнең икенче төр изафә бәйләнешендәге сүзтезмә хасил итеп кулланылуы күзәтелә: сабыр итәмен Хақ эшенә [Кандалый, 1988, б. 77], мәхәббәт атәшенә [Кандалый, 1988, б. 120] һ.б.

XIX гасырның икенче яртысында иҗат ителгән поэзия әсәрләрендә тартым мәгънәсенең төрки-татар теленә хас булган ысулы белән белдерелүе активлаша. I, II, III зат тартымының синтетик ысул белән белдерелү очраклары Ә. Уразаев-Кормаши кыйссаларының, чәчмә өлешенә караганда, диалогик формада бирелә торган тезмә өлешендә сан ягыннан арта: җан-җан йарым, дидарыңызны күрергә, без илеңә барғунча… [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 2–3]; қодрәтең киң, мәхәббәтем йарасын, ғыйшқым чиген күрмәсә, ул қадремне белмәсдер, қолағына элмәсдер [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 6–7], Серем илән сердәш син, Йулым илән йулдаш сән, Қулың миннән ал Таһир Син мәңа Қардәш сән [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 7], Сер илән сердәшем сән, юл илән юлдашым сән... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 8], ... Ғашыйқым сән, Таһирым, мәғшуқым сән, Таһирым [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 8] һ.б. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» дә I зат тартымлы исемнең аналитик-синтетик ысулы әсәрнең һәм тезмә, һәм чәчмә өлешендә кулланыла: Минем күңелемдә бер нийәтем бардыр, ... синең бер қыз балаң булып, ... бу минем қарендәшем дип белер иде, Зөһрә, минем җаным син, И минем Зөһрәм, и минем җан ярым ..., минем қызым падишаһ қызыдыр һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, аналитик-синтетик ысулдагы тартымлы исемнәрнең I зат берлек һәм күплек формалары актив кулланыла. Алар, төп мәгънәләре белән бергә, ярату, хөрмәтләү, соклану мәгънә төсмерләрен дә белдереп киләләр.

I зат тартымлы исемнәрнең синтетик төре, авторның шәхесе тасвирлана торган өзекләрдә активлаша. Г. Чокрый шигырьләрендә: Ләбибем дип сөяр иде атамыз, Әдибем дип сөяр иде анамыз... [Татар әдәбияты, 1957, б. 246] һ.б. Бу үзенчәлек М. Акмулла иҗатында дәвам ителә, I зат берлек һәм күплектәге тартым кушымчалы исемнәр эзлекле файдаланыла: Бәхетемез ачылмаған без бер фәқыйрь, Абруем артығы йуқ, эшем тақыр, Яшьтә җыйған бер буаз мәҗмағым бар [Акмулла, 1892, б. 3], «Җарүдә» иясенә сүземез юк, Аларға қаршы килер йөземез йуқ, ... Дөньяда сүземез бар, үземез йуқ [Акмулла, 1892, б. 10] һ.б. Гомумиләштерелгән зат истә тотылырга мөмкин: ... Йәше-

мез үткән саен күңлемез яшь [Акмулла, 2001, б. 50] һ.б. II зат тартымлы исемнәрнең синтетик төре автор мөрәҗәгать итә торган затка карatыла: Атың, чанаң, киемең күркәм булсын, ... Үзең симез, қорсагың өлкән булсын... [Акмулла, 2001, б. 51] һ.б.

Г. Тукайның башлангыч чор иҗатында тартымлы исемнәрне файдалануда традиция дәвам итә: а) тартым мәгънәсе гарәп-фарсы телендәге сыйфатлау һәм изафә тәркибе (тезмәләре) белән күрсәтелә: ...Безез әсхабе, әүляде бу ғасры мәғрифәт хәсрең [Тукай, 1985, б. 24]; ... Җиһанда мисле надир бер клубдыр, Сөрүрел-җан һәм нурел-қолүбдер [Тукай, 1985, б. 38] һ.б.; ә) һәр затка караган тартым мәгънәсе үзенең төп мәгънәсе белән файдаланыла. Мәсәлән, I зат күплек сан синтетик һәм аналитик тартымлы исемнәр күпчелекнең теләгең белдерә: И қаләм, сәндән кәлер һәп бәхтемез, иқбалемез, Бәкләнер дүрт күз илә лотфында истиқбалемез Кичмәсен қараңғылықта маһемез һәм салемез, Ғафилез без, җаһилез – вай хәлемез, вай хәлемез... [Тукай, 1885, б. 56]; ...Без күчәрбез, иң элек күчсен безем әмсарымыз, Һәм дә қайтсын монда үткәргән безем әғсарымыз... [Тукай, 1985, 186] һ.б.

Әмма алга таба һәр затка караган тартымлы исемнәрнең мәгънә эчтәлеге катлауландырыла. I зат берлек сан синтетик формадагы «җаным», «җанашым» исемнәре теге яки бу шигырь эчтәлеге өчен кирәк булган ироник төсмер белән кабатлана: Тот, җаным, тот аумасын – түп итмәсен, тот басқычын [Тукай, 1985, б. 225] һ.б. II зат синтетик һәм аналитик тартымлы исемнәр дә әлеге юнәлештә бирелә: Сөям чүмеч кеби борыңны, җаным, Ғашыйқ булдым, тәмам бетте мәҗалем, Җанашым, аһ, иләк awызыңны үпсәм, Ни қайғы, инде мин шул чакта үлсәм... [Тукай, 1985, б. 210]; Сөям сезнең сызылған қашыңызны, Тузылған сачыңызны, башыңызны, Сөям кәүсәрдән әхлә ирнеңезне, бу мақтауға ризалық бирдеңезме? [Тукай, 1985, б. 95] һ.б.

I һәм II затка эндәшелеп әйтелә торган тартымлы исемнәр төрле төсмерләр белән баетылып, сурәт ясау чарасына әвереләләр: «Ни қылырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр яқаң?» – дигән юлларда «абзам» сүзендәге I зат тартым кушымчасы якынлыкны белдерүдән бик ерак, ул кимсетүгә ымлый [Тукай, 1985, б. 240]. «Шүрәле» поэмасындагы: «Бу җегет абзаң булыр бу, бик белеп тор син, энем!» – дигән юлларда [Тукай, 1985, б. 171] *абзаң* һәм *энем* тартымлы исемнәре сөйләүченең үз-үзе белән горурлану һәм мактануын аңлата.

Күрсәтелгән вакытта хикәяләү хәбәр сөйләүчеләрдән ишетелгән һәм әсәр күчерүчеләрдән билгеле булган вакыйгалар сөйләнеп

бирелә торган беренче төрдә барганда, аерым персонажларның үзара фикер алышуына корылган өзекләрнең булуы да күренә. Менә шушы өзекләрдә бер персонаж икенчесенә, кем белән сөйләшүенә карап, ихтирамын белдерү йөзеннән, I зат берлек сандагы тартымлы исем белән сүзен башлый. Бу үзенчәлек К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда ачык чагылыш таба. Сөйли башлаучы, падишаһка хөрмәт белән, бер-бер артлы «И падишаһым, әфәндем, и шаһым» дип эндәшә. Башка персонажлар да берсе икенчесенә эндәшкәндә «И газизем вә миһербан кунагым, әфәндем, угылым, и газизә анам, җаным, дәүләтле солтаным, газизем, назниным, и җаным» кебек I зат берлек сандагы синтетик тартымлы исемнәрне куллана. Мисаллардан күренгәнчә, тартым күренешенең I зат берлек сандагы синтетик ысул белән белдерелү очрагы К. Насыйриның сәнгатьле проза әсәрләренең тел тукымасында, нигездә, хөрмәтләп мөрәҗәгать итү һәм ата-ана, угыл-кыз, баш-мал кебек адәм баласына бик якын һәм үз булган төшенчәләрне атаганда күбрәк кулланыла. «Әбүгалисина кыйссасы»нда I һәм II зат тартымының берлек һәм күплек сандагы аналитик-синтетик ысулы да файдаланыла: ...Әй падишаһым, мәнем егетләрем зиядә һөнәр вә санағать ияседер [Насыйри, 1898, б. 10]; ...сәнең фәһемең бу қадәр икән,... [Насыйри, 1898, б. 20]; И күзем нуры, бу минем хыялыммыдыр... [Насыйри, 1898, б. 23]; И минем дәүләтле солтаным,... [Насыйри, 1898, б. 24]; Минем бу дәрдемә бер чара итмәк кирәксән... [Насыйри, 1898, б. 26]; ...бу көнләр безнең башымызға бер ғаҗәп хәл вакыйғ булды... [Насыйри, 1898, б. 31]; ...безнең дә мәхәббәт төнемезнең ахыры җитеп,... [Насыйри, 1898, б. 34]; ...нахақ йирдә безнең канымызга керәсең ... минем эшем юкдыр[1898, б. 39, 1974, б. 253] ... . сезнең гамәлеңезгә караганда [Насыйри, 1898, б. 43]. Балалар өчен махсус төзелгән җыентыкларда урын алган хикәятләрнең текстларында да, нигездә, аналитик-синтетик ысул белән ясала торган тартымлы исемнәр күбрәк урын ала: Мәсәлән, В. Радловның «Белек» җыентыгында: мәнем қултық таяғымны алып киткән, мәнем аяғым, синең күзең мәңә юлымны күрсәтеп, ... сәнең урынында мән булсам, ... мәнем күңелем әле дә ачық [Радлов, 1872, б. 5–7] һ.б.

К. Насыйриның әсәрләрендә III зат тартым мәгънәсенең, синтетик һәм аналитик ысулда белдерелүенә караганда, янәшә килгән ике исем белән күрсәтелү очрагы ешрак кабатлана: сабақ балалары, сабыйлық дәрәҗәсе, Бохара вилаятендә, шәһәрнең изгеләре вә галимнәре [Насыйри, 1974, б. 209]; зәйтүн мае, мәғарәнең ишеге [Насыйри,

1974, б. 212]; Тәварих китапларында, ғаҗәм йортында, җиһан халқы, аның җәмалына [Насыйри, 1974, б. 221]; суғыш һөнәрендә, уғланының анасы, Хытай мәмләкәтенең қызлары, олы патшаның қызы, патшаның улына, ғыйшық утына [Насыйри, 1974, б. 222]; адәм сурәте, ғаскәр әһеленә [Насыйри, 1974, б. 226] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, бу төрдәге тартымлы исемнәрнең беренче һәм икенче төр изафә тәртибендә кулланылуы, төрле мөнәсәбәтләрне аңлатулары, аерым очракта, билгеле бер төшенчәнең атамасы булып лексикалашуын күрсәтә.

К. Насыйриның сәнгатьле прозасында да, башка стильдәге хезмәтләрендә дә, икенче һәм өченче типтагы төрки изафә белән параллель рәвештә, гарәп телендәге сыйфатлау вә изафә тәркибендәге һәм фарсы изафәсе кебек сүз тезмәләре киң файдаланыла: ...падишаһ уғылын ғыйльме һәйәт вә ғыйльме нөҗүм үгрәнмәк өчен остазға бирмеш иде [Насыйри, 1975, б. 222]; ...бу қадәр ғыйльме хикмәт белән қуәт вә қодрәтне күргәч, ... ғыйльме кимия, ғыйльме симия вә ғыйльме ихфа дөнйаға андан җәелде [Насыйри, 1974, б. 210] һ.б. Әмма әлеге текстларда төрле фәннәрнең исемнәре шактый аз кабатлана, аерым персонажларны мактап әйтелгән тезмәләр күбрәк кулланыла: ...иртәгесен падишаһлық диванына әркяне дәүләт вә әғяне солтанат җыелып, и ... хакиме Арсту нияад, ... и мәхбүбе җияан, ... вә Зөләйхаи заман вә фитнәи җан иде, ... и хакиме заман, и хакиме зу фөнүн, и хакиме зу фөнүн, и хакиме дана һ.б. Гарәпчә изафә тәркибе һәм фарсы изафәсе ысулындагы тезмәләр шул ук мәгънәне алып килә торган төрки изафәләре белән алмаштырылып та кулланыла: и күзем нуры, и назнин диляра и күңелем мивәсе, и минем җаным күңелем тәхтендә солтаным, әүля падишаһым, и җаным әфәндем, ғыйлем вә хикмәт иясе иде [Насыйри, 1974, б. 216] һ.б.

Әдәби текстларда алынма тезмәләрнең күбесе өстәмә рәвештә аңлатыла: Әбүғалисинаның вилядәтенә, ягъни туғанына... [Насыйри, 1974, б. 208]; ...әқсаи мәғрибдә, йәғни иң кояш баешы тәрафында [Насыйри, 1974, б. 209] һ.б. Бу типтагы тезмәләр К. Насыйриның фәнни хезмәтләрендә тәфсилләнмичә биреләләр: ғыйльме ғаруз, ғарәби ләфызлар, төрки ғазәл [Насыйри, 1974, б. 63–65]; мохтасар китаб, ибтидаи җәғрәфия, җәғрәфия голәмәсе [Насыйри, 1974, б. 83]; ысулы җәғрәфияи кәбир [Насыйри, 1974, б. 84–85]; остазе кямил, әркяне дәүләт, кабилел ғыйлем [Насыйри, 1975, б. 104–110]; ғыйльме нәбатат, хавассы нәбатат, ғыйльме зирагать [Насыйри, 1975, б. 76–78] һ.б. Татар телен өйрәнеп язылган хезмәтләрдә дә әлеге тәртип дәвам ителә.

Бу төрдәге сүз тезмәләре, билгеле бер дәрәҗәдә, Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда (1887) да кулланыла: Имде ошбу тәварих әһәлләрендән ничә төрле әсаре ғарибәне мөштәмил булған хикәят вә тәмсиләтләр зикер қылыныр ки, ... падишаһ руи зәминдән бер солтан ғосмани хәзрәтләре ошбу Тутыйнамә китабыны тәркиб қылырға [Фәизхан, 1896, б. 2] һ.б.

III зат күплек тартым мәгънәсе III зат алмашлыгы белән бирелә. Әлеге алмашлык берлек санда – *аның*, күплектә *анлар* һәм *аларның* формаларында чагылыш таба. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар телендә язылган текстларда *анлар* формасы язма традицияне саклау һәм дәвам итү булып, *алар* – җанлы сөйләмә норманың әдәби телгә күчеше булып кабул ителә. Мәсәлән Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда: ...аларның һәр қаюсында ничә вә ничә ғыйбарәтләр хасил булыр... [Фәизхан, 1896, б. 2].

Шулай итеп, татар прозасын хикәяләүнең беренче төрендә язылган әсәрләрдә, тартым категориясенең һәр заты берлектә һәм күплектә, шулай ук изафә тәртибендәге формаларында кулланылышта була.

Хикәяләүнең икенче төрендә язылган әсәрләрдә бара торган вакыйгаларны, укучысына мөрәҗәгать итә-итә, автор үз исеменнән сөйләп алып бара һәм шушы юнәлештә ул I зат берлек һәм күплектәге тартымлы исемнәрне мул куллана. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: Хәлбүки уқучыларым! Ул атасыны ..., «Н» қарйасына қайтамыз, ..., Қыш әсналәрендә хикәямездә язылыннан затларның мәғыйшәтләре ..., белешләремез Ғали бай вә Сибғатулла әфәнде ..., белешемез Хәнифә туташ, белешемез Хисаметдин менла... [Акъегет, 1886, б. 7].

I зат күплектәге тартым кушымчасы хикәяләүнең автор белән укучы исеменнән баруына ишарә итә. З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887) әсәре дә шундый ук ысул белән языла: Хикәямез ғаҗәеб гүзәл хикәядер. Хикәямезе яхшы аңлатмақ өчен ..., хикәямездән уқылып аңлашылачақ эш... [Бигиев, 1991, б. 221]; Сезләрә дә, хөрмәтлү уқучыларым, Мусаның ниндәләен адәм идекене белдерәем ..., [Бигиев, 1991, б. 223] һ.б. З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» (1890) әсәрендә укучыга турыдан-туры эндәшү азая, бер-ике урында гына калдырыла: ...яздығымыз Маһруйның йоқысы кеби йоқының вөҗүде уқучыйа, әлбәттә, мәғлүмдер [Бигиев, 1991, б. 281].

Ф. Кәрими, Р. Фәхретдин, Г. Гафуров-Чыгтай, Ш. Мөхәммәдов, З. Һади кебек мәгърифәтчеләрнең әсәрләрендә дә укучыга турыдан-

туры мөрәҗәгать итү, М. Акъегетнең романындагы кебек, системалы рәвештә дәвам итми, укучы белән элемтә һәрбер әдиптә берникадәр үзенчәлерәк төс ала, әмма персонажлар үзара сөйләшкәндә һәм бер-берсенә карап сүз башлаган вакытта назлы-иркә сүзләр тартым кушымчасы белән әйтелә, I зат тартымының синтетик төре еш кабатлана, шул ук вакытта аналитик-синтетек ысул да файдаланыла. Ф. Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә (1897): әй балам, әй балам, балам [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 221–222] һ.б. Р. Фәхретдиннең «Сәлимә яки гыйффәт» хикәясендә (1898): Күземнең нуры, җанымның рәхәте, қызым, қанымдыр, бу көндән сезнең җарияңездер, Аллаһе тағәлә мөбәрәк идеб бәңа һәм гүзәл мәғыйшәтеңезне күрмәк, әүладларыңызы қочағымда тәрбияләб үстермәк шатлықыны насиб итсен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 310] һ.б. Р. Фәхретдиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» хикәясендә (1903): пәйғамбәремез, боерыңыз, әфәндем, қызым, анам [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 320] һ.б.

Авторның үз сөйләме итеп хикәяләнә торган әсәрләрдә тартым категориясенең еш кына аналитик-синтетик ысул белән бирелүе күзәтелә. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә аналитик-синтетик ысулда бирелә торган тартымлы исемдә I зат алмашлыгының берлеге һәм шул ук алмашлыкның күплек күрсәткече угыз вариантында кулланыла: ...китереңез бәнем үз мәдрәсәмә... [Акъегет, 1886, б. 3]; ...безем меллаларға ағыз ачмаға да вирмәз [Акъегет, 1886, б. 8]; ...безем қағыйдә вә қанунларымыз... [Акъегет, 1886, б. 8]; ...безем аwыллы ятим Мохтар диләнчейе... [Акъегет, 1886, б. 14] ... бәнем эшеми кем эшләсен [Акъегет, 1886, б. 20] һ.б.

З. Бигиевның «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887) романында I зат алмашлыгының берлек һәм күплек саны шундый ук тәртиптә бара: ...бәнем үз атым көтәдер, бәнем эшем харап, бәнем занымча, ... бәнем хадимем, бәнем кулым, бәнем милкем һ.б. Бу әдип «бәнем» сүзен «мәнем» белән чиратлаштыра башлый: мәнем үвемдә һ.б. Әлеге күренеш авторның «Гөнаһе кәбаир» (1890) әсәрендә ешрак кабатлана: ...мәнем хақымны әда қылурсән [Бигиев, 1991, б. 21]; ...мәнем өемдә туғды... [Бигиев, 1991, б. 28]; мәнем сүзләремә инанмаган булғансән [Бигиев, 1991, б. 30]; мәнем сүзләрем-мәслихәтем тәмам булғаны юк [Бигиев, 1991, б. 32] һ.б. Әлеге әсәрдә тартымлы исемнәр ешрак аналитик ысулда, *бәнем, безем* алмашлыклары белән ачыклана: ...безем аwылның хәзердәге хәле [Бигиев, 1991, б. 6]; эткәсе безем мәхәллә имамы [Бигиев, 1991, б. 10]; безем авылның [б. 10]; безем

мөселманларның вә мәдрәсәләрнең [б. 28]. Аналитик-синтетик ысул белән кулланыла торган тартымлы исемнәр дә дәвам итеәә: безем аwылдашларымыз [Бигиев, 1991, б. 3]; безем сүземезгә генә инанмас... [1991, б. 254–288]. «Мавәрәэннәһердә сәяхәт» (1902) әсәрендә: ...безем Русия татарларында wар қадәр дин, безем әлдә нә қадәр исә дә [Бигиев, 1991, б. 290]; ...безем татарларың мәқальләре вар [Бигиев, 1991, б. 297]; шу көнге безем дәрәҗәи ғыйльмиямез, буңа тәбәға әхуәле сәйасиямез... [Бигиев, 1991, б. 290] һ.б.

Ф. Кәрими, мәгълүм булганча, үз чоры татар әдәби теленең өч варианты белән дә иҗат итә: сәнгатьле прозасы гавамлашкан әдәби тел белән, сәяхәтнамәләре иске татар әдәби теленең төрекләшкән, фәнни хезмәтләре исә гарәп-фарсы алынмалары күбрәк кулланыла торган вариантлары белән языла. Адресатның кем булуына карап, сүз һәм сүзформалар махсус сайлана, бу хәл тартымлы исемнәрнең кулланылышында да чагылыш таба. Сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә тартымлы исемнәр, эзлекле рәвештә, *минем* һәм *безнең* алмашлыклары белән, ә сәяхәтнамә һәм фәнни хезмәтләрендә, *бәнем* һәм *безем* вариантлары белән ачыклана торган аналитик һәм аналитик-синтетик төрдәге тартымлы исемнәр файдаланыла. «Салих бабайның өйләнүе» (1897) әсәрендә: ...безнең кыяр каравылчысы бер картыбыз бар иде ... минем иптәшем аның сүзене кисеп ... минем солдат өчен қаралырға тиеш wақытым, ... минем йулдашым, минем атам [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 220–229] һ.б. «Бер шәкерт илә бер студент»та (1900): ...безнең ақ җиләнле вә чапанлы кешеләр, минем бу исәбемнең, безнең пишкадәмнәребез, минем өстемдә, минем янымарақ һ.б. Әлеге әсәрдә «безем сихибелкомганлар» дигәндә авторның юморы сизелә, димәк, әлеге очракта «безем» махсус рәвештә сайланган булып аңлашыла [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 247], «Нуретдин хәлфә»дә: ...безнең Нуретдин хәлфә, безнең төрки ыруларында, безнең дамелла Нуретдин хәлфә, безнең Нуретдин хәлфәнең [Кәрими, 1996, б. 57] һ.б. Ф. Кәриминең «Морза кызы Фатыйма» (1901) әсәрендә вакыйга Кырымда бара, гомумтөркинең угызлашкан вариантына хас булган сүз һәм сүзформалар күбрәк кулланыла: ...бәнем фикеремә күрә, бәнем хәддем түгел дип әйтмәкче, бәнем wақытым йуқ, бәнем атам һ.б. *Безнең Фатыйма туташ, безнең йөземез, безнең икемез* кебек тартымлы исемнәр сирәк күренә [Кәрими, 1996, б. 83] һ.б.

Әдипнең сәяхәтнамәләре иске татар әдәби теленең җәдиди госманлы варианты белән языла, барлык төрки халыклар да укый алсын

дигән максат күздә тотыла, тартымлы исемнәрнең аналитик, аналитик-синтетик төрләре традицион язылышта бирелә: безем ки кәнҗлек ғаләме [Кәрими, 1996, б. 152]; безем янымызда [Кәрими, 1996, б. 155]; безем ислам ғолямасының [Кәрими, 1996, б. 157]; безем милләтемезнең [Кәрими, 1996, б. 160] һ.б.

Р. Фәхретдин иҗатында үз чоры әдәби теленнән файдалану тагын да катлаулырак. Аның сәнгатьле проза әсәрләренең теле халыкның җанлы сөйләменә бик үк якынайтылмый, традицион язма формалар эзлекле кулланыла. Авторның үз исеменнән бара торган өзекләрдә, тартымлы исемнәр I зат күплек һәм берлек сандагы аналитик һәм аналити-синтетик ысулда бирелә. «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә (1898): ...хикәятемез, үз хәлемезгә, безнең яздыкларымыздан әсәремезне [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 264] һ.б. Аналитик-синтетик тартымлы исемнәр, асылда, *бәнем* алмашлыгы белән күрсәтелә: бәнем қашымда [Фәхретдин, 1898, б. 17]; бәнем илтифатсызлығымны [Фәхретдин, 1898, б. 31]; бәнем эшем [Фәхретдин, 1898, б. 34] һ.б.

Синтетик ысулдагы тартымлы исемнәр белән бергә, аналитик һәм аналитик-синтетик ысул белән төзелгән тартымлы исемнәр беренче драма әсәрләренең текстында кабатлана. «Бичара кыз»да (1887): ...бәнем хәлем ничек үзгәрер... [Татар әдәбияты..., 1957, б. 555]; минем бу сөалемә, минем кулым түгел [Татар әдәбияты..., 1957, б. 556]; безнең аwылда, ... минем қулым түгел [Татар әдәбияты..., 1957, б. 557]. Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» драмасында (1888): Әни, минем күлмәк җыртықны күрмәсеннәр [Татар әдәбияты..., 1957, б. 575]; ...безнең әби әйтә торган иде [Татар әдәбияты..., 1957, б. 578]; ...безнең күрше Мәхүп кызы [Татар әдәбияты..., 1957, б. 579] һ.б.

Мәгърифәтче әдипләрнең иҗатында III зат тартымлы исемнәр барлык ысуллары белән дә кулланыла. М. Акъегет романында III зат күплек санының аналитик-синтетик ысулында, тартымлы исем иялек килешендәге *бунлар* күрсәтү алмашлыгы белән ачыклана: Хисаметдин менла бунларың батини әфкярләрене белмәеп,... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 54 б.]; ...гүя бунларың ике вөҗүдләрендә бер җандыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 45]. Шул ук функциядә зат алмашлыгының күплеге дә файдаланыла: анлар қызларыны ғаиб итделәр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 78]. Әмма бу алмашлык, исемнәрне алмаштырып килүче зат алмашлыгы буларак, ешрак кабатлана.

Шул ук вакытта, К. Насыйри әсәрләрендәге кебек үк, тартым кушымчасы алган исемнәрнең баш һәм иялек килешенәге исемнәр

белән ачыкланып файдаланылу очрагы рәттән кабатлана. «Хисаметдин менла» әсәрендә: татар аwылы, қарйәнең әһалисе, қарйәсенең ханәләре, менла қадыны [Акъегет 1886, б. 2] һ.б. Бу әсәрдә әлеге тезмәләрнең үзенчәлекле рәвештә кулланылуы күренә, ягъни ачыклана торган тартымлы исем янәшә тормаска да мөмкин: Әһалисенең башлыча мәгыйшәт өчен хезмәте игенчелекдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 45]; Хисаметдиннең мәрхүм атасы, қарйәнең указный менласы [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында да аналитик-синтетик ысулдагы тартымлы исемнәр иялек килешендәге *бунлар* алмашлыгы белән ачыклана һәм әлеге сүзтезмәләр рәттән тезелеп бара: ...шу wақыт бунларның бүлмәләренә кереп, ... бунларның қачуларыны белеп һ.б. Шул ук вакытта *анлар* алмашлыгы белән чиратлашу да күзәтелә: ...безне анларның йиренә ... юллады һ.б. Тартым кушымчасы алган исемнәрнең баш һәм иялек килешендәге икенче исем белән ачыкланып кулланылуы еш кабатлана: мулла-иман баласыдыр, Нәкәснең адыны, җомға намазы, мәсҗед қапусы, ходай юлында, мулла өендә, мәхәллә җәмағатенә, дин юлында [Бигиев 1991, б. 255]; сабах намазын, Қазан мәдрәсәләре, ... анларның йаманлықларындан, шәкердләрнең шу мордарлары [Бигиев 1991, б. 256]; хикәямезнең героинясы, ... өй Хуҗасы уғылы [Бигиев 1991, б. 257] һ.б.

М. Акъегет һәм З. Бигиев романнарында аналитик-синтетик һәм аналитик ысулдагы III зат тартымлы исемнәрнең фарсы изафәсе формасында кулланылышы сан ягыннан шактый күбәя.

З. Бигиевның сәнгатьле прозасы белән чагыштырганда, аның «Мавәраэннәһердә сәяхәт»ендә (1908) гарәп һәм фарсы изафә тәркибе файдалану тагын да күбәя: безем дәрәҗәи ғыйльмиямез, әхwале сәйасиямез, көтебе тарихийәдә әхуале тарихиясене, халифәте исламия, халифәте Габбасийә [Бигиев, 1991, б. 289] һ.б.

III зат тартымлы исемнәрнең һәр өч ысулда кулланылышы Ф. Кәрими һәм Р. Фәхретдиннең төрле жанр-стильгә караган әсәрләрендә, асылда, шушы тәртиптә бара, ягъни синтетик ысулның берлек *(-сы/-се)* һәм күплек саны *(-лары/-ләре)* кушымчалардан аңлашыла; аналитик һәм аналитик-синтетик ысулның берлек саны *ул* алмашлыгының иялек килешендә (*аның*), күплек санындагы тартымлы исемнәр, иялек килешендәге *алар, анлар, болар* һәм *бунлар* алмашлыклары белән ачыклана. Шуның белән бергә, бу авторларның әсәрләрендә, кайсы укучыны күздә тотып язуга карап, әлеге алмашлыкларны кул-

лануда графо-орфографик нигездә функциональ-стилистик аерымлану күзәтелә.

Ф. Кәриминең махсус рәвештә халыкның сөйләменә якын вариантта язылган хикәяләрендә традицион язма формалар һәм җанлы сөйләмә вариантлар, төрле дәрәҗәдәге синоним парлар буларак, бер үк сүзне кабатламау өчен файдаланыла. «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә: болар хақында, ...бонлар ғадәттән мәләкдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 225]; «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы»нда: ...боларның бәғзесе [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 242]; «Бер шәкерт илә бер студент» хикәясендә: ...аларның йанындағы руслар, аның йанындағы, боларның да яшел чапанлысы [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 248]; «Нуретдин хәлфә»дә: ...аларның фаразына күрә [Кәрими, 1996, б. 58]; ...бонларның хәлләре [Кәрими, 1996, б. 62]; анларның җирләрен [Кәрими, 1996, б. 63] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә (1898): ...бунларның қаберләренә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268]; бунларның йөзләренә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 272] һ.б. Башка әсәрләрдән дә мисаллар китерергә мөмкин, әмма шуны ассызыклап әйтергә кирәк, III зат тартымлы исемнәрнең, алмашлыклар белән ясалышына караганда, берсе иялек килешендәге ике исем белән кулланылуы бермә-бер күбрәк, эзлеклерәк. Шул ук вакытта, тартымлы исемнәрнең III заттагы мәгънәсе фарсы изафәләре белән дә күрсәтелә. Әлеге үзенчәлек сәяхәтнамәләрдә эзлекле рәвештә тезелеп бара һәм, авторның фәнни хезмәтләрендә дә күзәтелә.

Шулай итеп, мәгърифәтчеләр иҗатында тартымлы исемнәрнең алмашлыклар белән, иялек килешендәге ике исем белән кулланылышы, фарсы изафәсе белән файдаланылуы күзәтелә. Адресатка карап язылган әсәрләрдә фонетик-орфографик яссылыктагы вариантлылык белән функциональ-стилистик аерымлану да күренә.

Классик әдипләрнең иҗатында да һәр өч ысулдагы тартымлы исемнәр кулланыла, шул рәвешле язма традиция дәвам ителә. Бу, аерым алганда, Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1899) һәм «Кәләпүшче кыз» (1900) кебек беренче хикәяләрендә I һәм II зат күплек сан синтетик исемнәрдә, *-мыз/-мез* һәм *-ңыз/-ңез* кушымчаларының язылышында күренә: ...бөтен өй җәмәғатемезгә тигез ғомер бирсен [Исхакый, 1998, б. 42]; ...хәер-доғаларыңыз хақында, ... айлық имтиханымызда [Исхакый, 1998, б. 43] һ.б. Шуның белән бу әсәрдә үк *-мыз* кушымчасының, бер

мәртәбә, *-быз* белән чиратлаштырылуы күзәтелә: ...эллә ни байлыгыбыз юк [Исхакый, 1998, б. 38]. «Кәләпүшче кыз» әсәрендә: ...этиеңез сәламәт иде, ... кулымыз иркен иде, ғомеремезнең, дөнйаға килүемезнең рәхәтен күрә идек [Исхакый, 1998, б. 54] һ.б. «Капитан кызы» (1902) әсәрендә I зат *-быз,* II зат *-ңыз* кушымчасы белән бирелә: барасы җиребез [Исхакый, 1902, б. 6]; ...сезнең яхшылығыңызны онытмам [Исхакый, 1902, б. 10] һ.б. «Бай угылы» (1903) әсәрендә, авторның үз исеменнән бирелә торган керешендә дә, персонажлар сөйләмендә дә, тартым кушымчаларын *-мыз, -ңыз* формасында кулланылу дәвам итәлә: ...җәнабеңезгә, ... милләтемездә һ.б. [Исхакый, 1910, б. 159]. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә (1904): ...милләтемезнең, ... халкымыз арасында [Исхакый, 1998, б. 154]; ...байларымызның, бикәләремезнең, мәдрәсәләремез, мәктәпләремездә, шәкертләремезнең [Исхакый, 1998, б. 163–164] һ.б Шушы ук әсәрләрдә, зат алмашлыкларының эзлекле булып җанлы сөйләмә формада кулланылуы күзәтелә. «Тәгәллемдә сәгадәт...» әсәрендә: безнең халык ғыйлемгә карамый [Исхакый, 1998, б. 34]; безнең Хәлим дә сабакка житеш кенә, ... безнең халыкта шәфкать юк шул [Исхакый, 1998, б. 35] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, тартымлы исемнәр рәттән аналитик ысулда бирелә. Хис-кичерешләр тасвир ителгәндә, яисә фикер, үтенү төсмере белән әйтелгәндә, аналитик-синтетик ысулдагы тартымлы исем файдаланыла: минем шул шатлыклы көнемдә [Исхакый, 1998, б. 36]; ...үземезнең тора торған җирнең [Исхакый, 1998, б. 37]; безнең йомышыбыз [Исхакый, 1998, б. 40] һ.б. Әлеге үзенчәлек Г. Исхакыйның башка проза әсәрләрендә дә дәвам итәлә. Авторның аерым әсәрләрендә бирелә торган кереш сүзендә I зат берлек һәм күплектәге аналитик-синтетик ысулдагы тартымлы исемнәр фикерне конкретлаштыру вазифасын үти.

Г. Исхакый әсәрләрендә III зат күплек сандагы аналитик һәм аналитик-синтетик ысулдагы тартымлы исемне ачыклый торган алмашлыкның, график-орфографик яссылыкта, төрлечә кулланылуы күренә, ягъни халыкчан вариантлар традицион язма нормалар белән аралаштырып кулланыла.

Шуның белән бергә, Г. Исхакый әсәрләрендә дә III зат тартымлы исемнәрнең, иялек килешендәге алмашлык белән ачыклануына караганда, баш яки иялек килешендәге исемнәр белән белдерелүе активлык күрсәтә. «Тәгаллемдә сәгадәт...» әсәрендә: ағачларның яфраклары, үләннәрнең чәчәкләре, җәй фасылының бетүенә, кошларның та-

вышлары, суларның дулқынлары, мулла балалары [Исхакый, 1998, б. 31]; «Кәләпүшче кыз» әсәрендә: ата мәхәббәте, ... иренең wафатына, ... Кәримәнең күңлендә [Исхакый, 1998, б. 52] һ.б. Шулай итеп, Г. Исхакыйның сәнгатьле проза әсәрләрендә тартымлы исемнәрнең берлектәге һәм күплектәге һәр III заты да барлык ысулларда да файдаланыла, халыкчан вариантлар белән яңартыла бара. Бу үзенчәлек авторның сәхнә әсәрләре өчен дә хас.

Шул ук хәл Ф. Әмирханның барлык жанр-стильдә язылган әсәрләрендә дә чагылыш таба. I зат синтетик тартымлы исемнең күплектәге *-мыз/-мез* формантын куллану тулаем иҗаты буенча дәвам итә. «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә (1907): ...бер-беремезне, милли театрларымызның артист вә артисткалары [Әмирхан, 1984, б. 7]; «Милләт тәрәкъкый иттерү»дә (1908): мәдрәсәләремездә [Әмирхан, 1984, б. 33]; ...Заманымыз – заманы тәрәқый [Әмирхан, 1984, б. 34]; «Танымаганлыкдан таныштык» (1909) әсәрендә: Әйе, киемнәремез күп үзгәрә, ләкин үземез аз үзгәрәмез... [Әмирхан, 1984, б. 63] һ.б. Бу үзенчәлек авторның хатлары өчен дә хас.

Ф. Әмирхан үзенең каләмдәшләреннән аермалы буларак, традицион тартым кушымчасын стилистик чара буларак файдалана. «Танымаганлыктан таныштык» әсәрендә автор җанлы сөйләмне бирергә теләгәндә *-быз* формантын куллана: Ә без все-таки аларга үзебезнең кем икәнлегебезне танытырбыз [Әмирхан, 1909, б. 25].

I заттагы күплек тартым кушымчасыннан аермалы буларак, II зат күплектәге тартым күрсәткече *-ңыз* Ф. Әмирхан иҗатының башлангыч чорында ук сөйләмә *-гыз* формасы белән чиратлаштырылып алып барыла. «Бәйрәмнәр» хикәясендә (1908): Барыңыз, алай булса, шулай бөтен халық алдында хатын-қызларыңыз белән қочақлашып биеңез [Әмирхан, 1984, б. 24]; «Милләт тәрәкъкый иттерү» (1908) хикәясендә: Мин дә басып уқыр идем дә, барығызға да башларығызны сузып қарарға кирәк булыр дип қурқам [Әмирхан, 1984, б. 39]. Ике җөмләдә дә юмор белән тасвир ителә торган персонаж сөйләме бирелә, ләкин икесе ике төрле языла. Икенче җөмләсе белән автор милләтне тәрәкъкый иттерү юлында йөргән озын мишәрнең наданлыгын, ягъни сөйләшүенең дә рәте булмаганлыгын тасвир итә. «Танымаганлыктан таныштык» (1909) хикәясендә дә элеге формант үзенең хәзерге әдәби варианты белән чиратлашып кулланыла: Ялғанымыз тотылмасын өчен [Әмирхан, 1984, б. 64]; ...кирәк сүзегезне ишеттегезме? [Әмирхан, 1984, б. 72]; ...Нинди мөхәррир-

ләреңез бар? [Әмирхан, 1984, б. 75]. Бу өч җөмләне дә хикәяне алып баручы үзе әйтә. Формантларның чиратлашуы тыңлаучыларның кем булуы белән бәйле булса кирәк: җанлы сөйләмә форма белән ул исерек Гайсага эндәшә. Әмма дустанә эндәшергә кирәк булганда да, шушы ук кушымча сайлана. «Хәят» (1911) повесте һәм «Кадерле минутлар» (1912) хикәясендә дә әлеге морфеманың традицион язылышы һәм сөйләмә варианты чиратлаша. Ул рәсми-югары тондагы сурәтне бирергә кирәк булганда – *-ңыз,* ә инде гадиләшә баруны күрсәтергә кирәк булганда *-гыз* кушымчасы куллана. Урыны-урыны белән әлеге формантлы исемнәрнең чиратлашуында эзлеклелек җимерелә: ...чәчләреңезгә қадаған матур нәрсәгез (қалфақ) булмаса, мөселман қызы дип тә танып булмас иде, ... чәчегезгә қадаған нәрсәгез бик матур [Әмирхан, 1911, б. 19]. «Урталыкта» (1912) романында да шундый ук алмаштырылып куллану күзәтелә. Әдипнең кайбер хикәя һәм повестьларында тартым күрсәткечләренең традицион язылышы әсәрдәге гомуми атмосфераны саклау өчен бернинди чиратлашусыз гына да файдаланыла. Мәсәлән, «Фәтхулла хәзрәт» (1909), «Көндезге сәхәр яки рузасызлар» (1911), «Ай өстендә Зөһрә кыз» (1912), «Хәзрәт үгетләргә килде» (1912) әсәрләрендә әлеге алым, ягъни традицион кушымчалы сүзләр, ироник образны тасвирлау чарасы булып сайлана.

Шулай итеп, I һәм II зат берлек һәм күплек сандагы тартымлы исемнәр классик язучылар иҗатында үзләренең һәм традицион, һәм халыкчан формалары белән образ барлыкка китерү чарасы буларак файдаланыла.

Ф. Әмирхан I һәм II зат аналитик һәм аналитик-синтетик ысулда тартымлы исемнәрне яратып куллана: безнең мәхәлләдә [Әмирхан, 1984, б. 16]; ...безнең бала бәғзе бай балалары шикелле [Әмирхан, 1984, б. 19]; ...атасы һәйбәт кеше, безнең бик дустлардан иде [Әмирхан, 1984, б. 21]; ...сезнең мәхәббәтеңезне [Әмирхан, 1984, б. 28]; ...минем мәхәббәтемне [Әмирхан, 1984, б. 29]; ...минем күңелемне [Әмирхан, 1984, б. 68] һ.б.

Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатында язылган хикәяләрендә дә тартымлы исемнәр шушы тәртиптә кулланыла. I һәм II заттагы тартымлы исемнәр синтетик ысулда традицион кушымча белән кулланыла. «Гыйшык корбаннары» хикәясендә (1908): нурлы йөзләреңезгә, қара алтындай сачләреңезне, ғакде ниқахымызны [Ибраһимов, 1974, б. 458]; баламызны, йортымызға, ихтималымыз [Ибраһимов, 1974, б. 462]; уғлыңыз [Ибраһимов, 1974, б. б. 472] һ.б. Берлек сандагы I һәм

II заттагы тартымлы исемнәрнең күбрәк аналитик-синтетик ысулда, күплек санда исә аналитик ысулда файдаланылуы күренә. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) хикәясендә: ...минем утынымны кисәләр [Ибраһимов, 1974, б. 403]; ...сезнең аwылда [Ибраһимов, 1974, б. 404]; ...безнең бичара Зәки [Ибраһимов, 1974, б. 406]; безем шәкертләр [Ибраһимов, 1974, б. 412]; ...безем Зәки мәхдүм [Ибраһимов, 1974, б. 413]; «Гыйшык корбаннары» (1908) хикәясендә: мин сезнең бәндәңез [Ибраһимов, 1974, б. 452]; безем хәятымызны [Ибраһимов, 1974, б. 460]; «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1909) хикәясендә: безем милләтнең [Ибраһимов, 1974, б. 478]; синең тәнәззелеңне [Ибраһимов, 1974, б. 479]; безнең шәкертлек [Ибраһимов, 1974, б. 485]; минем сөәлемә [Ибраһимов, 1974, б. 490]; «Яз башы» (1910) хикәясендә: минем мәктәптәге тормышны [Ибраһимов, 1974, б. 52]; минем укуым, иптәшләрем, имтиханларым [Ибраһимов, 1974, б. 52]; безнең юкәдән ясалган тубаллар, безнең алдыбызда – барачак юлыбызда [Ибраһимов, 1974, б. 55] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, XX гасырның беренче унъеллыгына кадәр язылган матур әдәбиятның барлык жанрларында да тартымлы исемнәрнең, синтетик төре белән бергә, аналитик-синтетик төрләре актив кулланыла, шулай ук аналитик ысулдагы тартымлы исемнәр дә күзәтелә, I зат күплектәге зат алмашлыгы фонетик-орфографик яктан һәм традицион, һәм халыкчан формасын саклаган хәлдә кулланыла.

Шушы ук хәлне, ягъни билгеле бер әсәрдә традицион язма формалар, аларның җанлы сөйләмгә хас булган вариантлары кулланылуын, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан әсәрләрендәге кебек, Ш. Камал, М. Гафури, Г. Тукай һ.б. иҗатларында да күрәбез. Алда әйтеп үтелгәнчә, классикларыбыз да бу төрдәге чиратлашулар, нигездә, ике вазифа үти: а) бер үк төшенчәнең һәр ике формасы да гадәти мәгълүмат бирү чарасы булып тора, ә) махсус рәвештә сайланып кулланылганда, сурәт-образ барлыкка китерү өчен файдаланыла.

Классик әдипләр иҗатында да, III заттагы тартымлы исемнең зат алмашлыгы белән бирелүенә караганда, берсе баш яки иялек килешендәге ике исем белән ачыклану һәм фарсы изафәләрен куллану дәвам ителә. Шул ук вакытта бу төрдәге төзелмәләр дә образ барлыкка китерү чарасы буларак файдаланыла, ягъни теге яки бу фикерне әйтеп бирү чарасы буларак та һәм аерым персонажларның характерын-сөйләмен сүрәтләү, аларга карата авторның мөнәсәбәтен күрсәтү чарасы буларак та кулланыла. Ф. Әмирханның «Милләт тәрәкъкый

иттерү» (1908), «Фәтхулла хәзрәт» (1909), Г. Исхакыйның «Мулла бабай» (1910), Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» (1912) һ.б.ш. әсәрләрдә фарсы изафәләренең функциональ-стилистик вазифасы ачык сиземләнә. Аерым әдипләрнең 1912–1914 еллардан соң язылган әсәрләрендә бу төрдәге чаралардан файдалану шактый пассивлаша, алар халыкчан төрки изафә белән алыштырыла.

XIX гасыр – XX гасыр башы татар әдәби телендә тартым категориясе турында фикер йөрткән вакытта, хәзерге әдәби телдә сирәгрәк күренә торган, ягъни I, III зат тартым кушымчасының исемне ачыклап килә торган сыйфат фигыльгә күчү очраклары игътибарны җәлеп итә. Бу үзенчәлекне, сыйфат яисә исем фигыльнең исемләшүе нигезендә эш-хәлнең башкаручысын белдерә, дип әйтергә була [Хисамова, 2006, б. 105], ләкин, хәзерге телдән аермалы буларак, тартым кушымчасын алган фигыль янында аңа бәйләнгән исем үзе дә кулланыла, тартым күрсәткечен аңа күчереп әйтергә, яисә тартымлы фигыльне исемләшмәгән варианты белән алмаштырырга мөмкинлек саклана.

Г. Тукай әлеге мөмкинлекне «Исемдә калганнар» язмасының сүзбашы итеп бирелгән «Мокатдимә»сендә файдалана: ...Уральскига килеп җиткәнемә қадәр кичердегем хәлләр илә аннан соң шушы сатрларны язып утырған wақытыма қадәрге башыма килгәнләрне икесен ике рисалә итеп чығарырға мәғкуль күрелде [Тукай, 1956, 4 т., б. 11]. Авторның «Халык әдәбияты» хезмәтендә: ...мисал итеп китергәнем шиғырьләр – барчасы да сонғый җырулардыр [Тукай, 1985, 4 т., б. 181] һ.б.

Әлеге вариантлылык функциональ-стилистик вазифа үти: К. Насыйри, Ә. Уразаев-Кормаши, Г. Фәезхановның чәчмә һәм тезмә кыйссаларында, беренче драма әсәрләрендә ул юк дәрәҗәсендә аз күзәтелә. Җәдиди госманлы юнәлешендә иҗат итүче мәгърифәтче әдипләрдән М. Акъегет, З. Бигиев, Ф. Кәрими һәм Р. Фәхретдин иҗатында эзлеклерәк файдаланыла. Классик әдипләрдән Ф. Әмирханның хикәя һәм романнарында, башкалары белән чагыштырганда, берникадәр дәвамлырак күзәтелә. Төрле чорда язылган әдәбиятта төрле дәрәҗәдә кулланылса да, бу төрдәге тартымнан файдалануда билгеле бер уртаклык саклана: ул, нигездә, I затта активрак, III затта азрак, II затта күзәтелми.

XIX гасыр – XX гасыр башы татар әдәби телендә тартым категориясенең синтаксиска нигезләнгән тагын бер норма вариантлылыгы күзәтелә. Бу – аналитик һәм аналитик-синтетик ысулдагы тартымлы исемнәрдә зат һәм предметның кайсы затка караганлыгы, зат алмаш-

лыклары белән рәттән, төрки телләр үсешендә бер сүз булган дип гоман ителә торган kendöz < kändi [käntü] + öz [СИГТЯ, 1988, с. 207], соңыннан ике сүз булып кулланылышта йөри торган *кәнде* һәм *үз* сүзләре белән дә тәгъбир ителә алуы. «Әбүгалисина»да: ...үзенең итагатенә өндәде [1898, б. 5] һ.б. Хәзерге татар телендәге кебек үк, тартым мәгънәсен алып килә торган *үз* сүзе, зат алмашлыкларыннан аермалы буларак, тартым һәм килеш кушымчалары белән дә, алардан башка гына да вазифасын үти ала, *кәнде* сүзенең кулланылышында да шушы ук тәртип саклана.

Әлеге ике алмашлык махсус рәвештә сайланып алып файдаланыла, ягъни иске татар әдәби теленең абруйлы һәм җәдиди госманлы вариантлары белән язылган әсәрләрдә – *кәнде*, халыкның җанлы сөйләменә якынайтып язылган әсәрләрдә *үз* сүзе кабатлана, димәк аларның кулланылышында функциональ-стилистик вариантлылык күзәтелә.

*Кыскача нәтиҗәләр.* Грамматик категориаль мәгънәсе буенча бер затның яисә предметның II зат яисә предметка каравы, предметлар арасындагы мөнәсәбәтләрне махсус ысул һәм кушымчалар ярдәмендә белдерә торган тартым категориясе дә, сан категориясе кебек үк, ике телгә хас булган әдәби норма күрсәткечләре белән тәгъбир ителә: беренчедән, хәзерге татар әдәби теленә хас булган I, II, III затларда – синтетик, I, II затларда – аналитик, I, II, III затларда аналитик-синтетик, III затта ике исем арасындагы төрле мөнәсәбәтне белдерү ысулында [Татар грамматикасы, 2002, б. 40]; икенчедән, гарәп-фарсы телендәге сыйфатлау һәм изафә тәркибе (тезмәләре) белән.

Әлеге ике әдәби норманың түбәндәге вариантлары күзәтелә:

1) графо-орфографиягә нигезләнгәне: а) I, II зат тартымлы исемнәрнең синтетик берлектә – *-м, -ң,* синтетик күплектә – *-мыз, -ңыз* һәм *-быз, -гыз* формасында язылуы; б) I зат берлектәге аналитик ысулда алмашлыкларның – *бәнем*, *мәнем*, *минем*, күплектә – *безем*, *безнең*, II затта – *сәнең*, *синең*, III затта – *анлар*, *алар*, *бунлар*, *болар* вариантларының кулланылуы; в) II һәм III зат берлек һәм күплек морфемасында [н] авазының төрлечә бирелеше: نك, نڭ, نکـ, نگـ;

2) морфологиягә нигезләнгәне: а) I, II, III затка караган тартым мәгънәсенең синтетик һәм аналитик-синтетик ысулда, I, II зат тартымның тагын аналитик ысулда да чагылышы; ә) III зат тартымлы исемнәрнең *-сы, -ы, -лары* кушымчаларын алуы; б) III зат тартымлы исемнәрнең, иялек килешендәге алмашлык белән ачыклануына караганда, баш яки иялек килешендәге исемнәр белән күбрәк

кулланылуы, тартым мәгънәсеннән башка мәгънәләр дә белдерә алуы; г) I, II, III заттагы тартымлы исемнәрдә тартым күрсәткечләренең исемне ачыклап килә торган сыйфат фигыльгә дә күчә алуы һ.б.

3) синтаксиска нигезләнгәне: а) аналитик һәм аналитик-синтетик ысулдагы тартымлы исемнәрдә зат һәм предметның кайсы затка караганлыгы зат алмашлыклары белән рәттән тагын *үз* һәм *кәнде* сүзләре кулланылып та белдерелә алуы, зат алмашлыкларыннан аермалы буларак, әлеге сүзләрнең тартым һәм килеш күрсәткечләреннән башка да килүе; ә) III затка караган тартымның III зат тартым кушымчалары белән (синтетик), иялек килешендәге III зат һәм күрсәтү *(бунлар)* алмашлыгы белән (аналитик-синтетик), шулай ук тагын берсе иялек килешендәге ике исем белән дә тәгъбир ителә алуы; б) янәшә килгән ике исемнең беренчесе баш килештә, икенчесе тартым кушымчалы булганда, тартым мәгънәсеннән башка мәгънәләрнең белдерелә алуы, лексикалашкан тезмәләр буларак кулланылуы һ.б.

Тартым категориясендә әдәби норма һәм норма вариантлылыгын тәшкил итә торган әлеге парадигмадан, авторның кайсы укучыны күздә тотып язу максатына туры китереп, яисә аерым бер стильнең берәр жанр-төренең таләбе белән махсус рәвештә сайланып кулланылуы функциональ-социаль яки функциональ-стилистик вариантлылыкны барлыкка китерә.

*Килеш категориясе.* Грамматик категория буларак, мәгънәсе буенча, исемнәрне башка сүзләр белән бәйләп, аларның синтаксик вазифалары (ия, тәмамлык, аергыч, хәбәр) нигезендә морфологик яктан субъект, объект, ачыклаулы мөнәсәбәтләрне белдерү мөмкинлегенә ия килеш категориясе, махсус система булып берләшә торган аерым килешләрнең хосусый кушымча-формаларында чагылыш таба [Татар морфологиясе, 2002 б. 45; Хисамова, 2006, б. 75–79].

Гомумтюркологик хезмәтләрдән аңлашылганча, исемнең гасырлар буена формалашып барлыкка килгән килеш белән төрләнешен (килеш категориясен), төрки телләр тарихының төрле хронологик этапларына бүлеп карарга мөмкин [СИГТЯ, 1988, с. 28–29]. «Языки мира: Тюркские языки» дигән энциклопедик хезмәттә (1997) борынгы һәм хәзерге телләрнең барысында да килеш категориясе җентекләп анализлана.

Татар теленең XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында язылган сарыф вә нәхү дәреслекләрендә килешләрнең саны төрлечә күрсәтелә [Татар грамматикасы, 2002, б. 45–48]. Мәсәлән, К. Насыйриның «Әнмүзәҗ»ендә (1895) алты килеш күрсәтелә [Насыйри, 1975, б. 66].

М. Өметбаевның «Татар нәхүсенең мохтәсары» (1902) дәреслегендә әлеге мәсьәлә түбәндәгечә яктыртыла: «...татар телендә исемнең азагына бәгъзе кисәкләр вә адәтләр кушылу илән төрле хәлгә төшә, исемләрнең андый хәлләрене күндерү диләр, ... бу хәлләрнең дәрәҗәләрен дөшем диләр, әмма тәгълим өчен, исемнең төбе илән җанлыга йиде, җансызга алты дәрәҗә дөшем җәдвәле кылганлар: исем дөшеме – кул, изафә дөшеме – кулның, бирү дөшеме – кулга, булдыру дөшеме – кулны, чакыру (нида), мәдәд дөшеме – кул берлән, кулдан, зарф дөшеме – кул хакында» [Өметбаев, 1902, б. 9].

Г. Нугайбәкнең «Төрлек» хезмәтендә килешләр шулай ук «төшем» дип атала: атау төшеме, тарту төшеме, бирү төшеме, күчү төшеме, чыгу төшеме, урын төшеме. Г. Ибраһимовның «Татар сарыфы»нда исемнәрнең килеш белән төрләнеше тикшерелми. Татар телендә килеш термины М. Корбангалиевның һәм Х. Бәдигыйның «Ана теле сарыфы», «Ана теле нәхүе»ндә (1918) кулланылыш ала. Г. Алпаров хезмәтендә: «Бездә исемнәрнең 3 рәт килеш төрлекләре сигез. Шуңа карап, исемнәр 8 төрле килештә булалар: баш килеш, иялек килеше, чыгыш килеше, юнәлеш килеше, төшем килеше, вакыт-урын килеше, рәвеш килеше, ошату килеше бар», – дип белдерелә [Алпаров, 1945, б. 102]. Л. Җәләйнең «Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар)» дигән хезмәтендә: «Борынгы төрки телнең грамматитк төзелешендә килеш категориясенең инде нигездә оешып җиткән булуын күрәбез. VI–VIII йөздәге Орхон-Янәсәй язмаларында баш килеш (билгесез килеш), иялек, төшем, юнәлеш, урын-вакыт һәм корал килешләренең булуы ачык теркәлгән», – дип, боларның һәрберсе мисаллар белән күрсәтелә, *ичрә, эчрә* ярдәмлегенең килеш функциясендә кулланылуы һәм килеш кушымчаларының этимологиясе аңлатыла [Җәләй, 2000, б. 15–31]. В. Хангилдинның хезмәтендә: «Татар теле грамматикасында килеш – иң киң күләмдә кулланыла торган грамматик категорияләрнең берсе», – дип, хәзерге әдәби телдә өйрәтелә торган алты килеш санала, аларның форма, мәгънәләре һәм синтаксик функцияләре аңлатыла [Хангилдин, 1954, б. 70–82]. Хәзерге татар әдәби телендә килешләрнең саны, форма һәм мәгънәләре хакында төрле карашлар яши [Зәкиев, 1964; Ганиев, 1970; Тумашева, 1978], әмма мәктәп дәреслекләрендә дә, академик грамматикаларда да традицион алты килеш бар дип санала [Татар грамматикасы, 2002, б. 49], ләкин мәсьәләне тәгаенләргә тырышып, яңа мәкаләләр дөнья күрә тора [Ирисов, 1992, б. 247–249; Сәмирханова, 1995, б. 88–96] һ.б.

Тел күренеше буларак өйрәнелгән вакытта килешләр өч аспекттан карап тикшерелә: морфологик формасы, грамматик мәгънәсе, синтаксик функциясе [Татар грамматикасы, 2002, б. 50]. Килешләрне сөйләм (текст) берәмлеге буларак тикшергәндә, әлеге категориянең функциональ-стилистик мөмкинлеген билгеләүгә дә, ягъни аерым текстта кайсы вазифаларының ешрак кабатлануына игътибарны юнәлтергә кирәк була [Бәширова, 1999, б. 109; Гайнуллина, 2010, б. 41].

Күрсәтелгән вакытта иҗат ителгән әсәрләрдә нуль формалы баш килештәге исемнең Аллаһы Тәгаләгә, аның әсмаи-хөснә, ягъни исме-әгъзамларына, ислам дөньясында танылган шәхесләргә мөрәҗәгать итеп, аларны эндәш сүз буларак кулланылу функциясенең эзлекле баруы игътибарны җәлеп итә. Ә. Каргалый «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви-әс-Сәгыйди» әсәренең (1845, 1889) аерым бүлекләрен Аллаһы Тәгаләгә инануын белдергән мөнәҗәте белән тәмамлаганда, аның исме-әгъзамларына эндәшеп, үзенә теләктәшлек, ярдәм көтә: Берлекеңнең хөрмәтенә, йа Кәрим, Дөнйадин кичер безе сағу-сәлим, Һәм вөҗүдең хөрмәтенә, йә Вәдүд, Безләрә тәуфыйқ у фазлың әйлә җүд. ... Ул Хәбибең хөрмәтенә, йә Илаһ, Кәчәрәсән бездән улса, һәр гөнаһ. ... Рәхмәт идеб әйләгел Фазлу-у-Кәрам... [Каргалый, 1889, б. 4–5] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, баш килештәге ялгызлык исемнәре эзлекле рәвештә эндәш сүз буларак кулланыла, аерым очракта I зат берлек сандагы тартым кушымчасы белән бирелә.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыл адәб» әсәрендә дә сүз Аллаһыга инану юнәлешендә бара: Кабул ит йа Аллаһы (آللهی), итмә мәхрүм, һәм абаи өмһатем илә мәрхүм... [Салихов, 1856, б. 2] һ.б.

Ш. Зәки иҗатында Аллага эндәшү дәвам ителә: Иляһы, пәрдәи күтәр күземдән, Мәғасый қарасын юғыл йөземдән, Иляһы, мөбтәлә қалдым, әлем тот, Ки бәңа һич мәдәд йуқ кәнд-үземдән [Гайнетдин, 2002, б. 33]; Иляһы, әйлә қурқулардан азат, Иляһы, әйлә иршад, әйләгел шат [Гайнетдин, 2002, б. 37]; И Ходаwәндәм, сиңадыр ибтияал [Гайнетдин, 2002, б. 43]; Рәхмәтеңдин күз тотубән, и Җәлил [2002, б. 59]; Теләгем сәндин боны, и Зөлкәрам ..., Юкса дишвәр улды халем, и Ғани, Хажәтем сәндин теләрмән, и Хода [Гайнетдин, 2002, б. 60] һ.б. Шулай итеп, Ш. Зәки шигырьләрендә Аллаһы һәм аның исме-әгъзам атамаларының баш килештә, эндәш сүзләр булып эзлекле кулланылуы күзәтелә. Автор тарафыннан, инану, ялыну, үтенү кебек мөнәсәбәт белдерелгәндә, билгесез килештәге исем, башка төрле килештәге сүзләр белән киңәйтелеп тасвирлана.

Аллаһы Тәгаләгә, Мөхәммәд пәйгамбәргә яисә аерым затларга эндәшеп язу башка авторларда да (Г. Чокрый, М. Акмулла, Я. Емельянов һ.б.) дәвам итеңә. Укучысына эндәшү алымын Г. Тукай да яратып куллана. Дәрдемәнд шигырьләренең дә күбесе җанлы затларга һәм җансыз предметларга эндәшү белән башлана. Шулай итеп нуль формалы баш килештәге исемнең эндәшү функциясе поэзия әсәрләрендә гасырлар дәвамында актив файдаланыла. Баш килешнең башка функцияләренә килгәндә, аларның күбесенең хәзерге татар әдәби теле нормасында кулланылуы күренә.

XIX гасырда, гарәп һәм фарсы алынмалары мул файдаланылып, абруйлы төрки-классик иске татар телендә язылган поэзия әсәрләрендә алдагы чорларда төрки-татар телендә язылган әсәрләрдән килә торган традиция дәвам итеңә. Иялек, юнәлеш, төшем килешләренең угыз телләренә хас булган формалары белән дә кулланылып, кыпчак төрләнеше белән мөнәсәбәттә вариантлылык хасил булуы күзәтелә. Әлеге вариантлылыкның төрле авторда төрле дәрәҗәдә баруы игътибарны җәлеп итә. Бу үзенчәлекнең тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнешендә дә чагылыш табуы күренә.

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви-әс-Сәгыйди» әсәрендә (1845) иялек килеше эзлекле рәвештә угыз төрләнеше тибында, ягъни исемнәргә *нун* белән *кәф* кушмасы рәвешендә языла торган *-ң* (نك-) аффиксы ярдәмендә белдерелә, сирәк очракларда аерым *кәф* графемасы (ك-), төрки-татар сүзләрендә сирәк очракларда *-ның* кулланыла. Мәгънәсе буенча, бу килеш нинди дә булса конкрет мәгънәле, яисә абстракт мәгънәле исемнең аерым затка, яисә аерым предметка каравын билгелелек төсмере белән белдерә. Бу әсәрдә өченче төр изафә бәйләнешендәге сүзтезмәләр, ягъни иялек килешендәге исемнең III зат тартымлы исемне ачыклап килү очраклары еш кабатлана, тартым кушымчасы язуда белдерелми: Хәлилең (حليلنك) қапусындан [Каргалый, 1889, б. 3]; әнсарың (انصارك) бере [Каргалый, 1889, б. 4]; Хәбибең (حبيبنك) өммәте, Кәримең (كريمنك) сөннәте, аның (آننك) әсхабе, берлекеңнең (برلكنكننك) хөрмәтенә [Каргалый, 1889, б. 4] һ.б.

Икенче төр изафә бәйләнешендәге сүзтезмәләр сирәк кулланыла: Сияһ итмеш Сафиулла бәхетен [Каргалый, 1889, б. 6]; حق رحمتنى – Хақ рәхмәтене [Каргалый, 1889, б. 7]. Мисаллардан күренгәнчә, тартым кушымчасы язуда күрсәтелми, транскрипцияләгәндә, традицион язылыш сакланырга да, хәзерге әдәби телдәгечә *-ның/-нең* кушымчасы белән күрсәтелергә дә мөмкин.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыл адәб» әсәрендә (1856), Ә. Каргалыйдан аермалы буларак, иялек килеше эзлекле рәвештә *нун* һәм *кәф* кушмасы (ـنك) белән билгеләнә, тартым кушымчасы язуда күрсәтелми: اسمنك سننك – сәнең исемең, Хәбибнең (حب نك) күңледә, ғаләмнең (عالمنك) сән Ходасы, [Салихов, 1865, б. 2]; нәзар кылдым у хәбелнең (حبلنك) бер башына [Салихов, 1856, б. 4]; җиһанның (جهاننك) әүвәленә ахырына [Салихов, 1856, б. 5] һ.б.

Ш. Зәки шигырьләрендә, сүз сузыкка тәмамланса да, тартыкка тәмамланса да, иялек килеше, *нун* һәм *кәф* кушмасы (ـنك)рәвешендә языла торган *-ң* аффиксы белән күрсәтелә: Ходаның (خدانگ) бер ғарибе, ғашиқ ашөфтәнең (آشفته نك), ғашиқ шүридәнең (شوريد ه نك) [Фәхретдин, 1907, б. 418; Юсупов, 2006, с. 192]. Димәк, Ш. Зәки шигырьләрендә иялек килешенең формасы исемнең вокализмына бәйле дип әйтергә [Юсупов, 2006, с. 32] җирлек күренми. Ә. Каргалый һәм Һ. Салихов әсәрләреннән аермалы буларак, кайбер сүзләрдә иялек кушымчасыннан алда, III зат тартым кушымчасының сузыгы язылырга мөмкин: фикренең (فكرينگ) дәрйасына [Фәхретдин, 1907, б. 418; Юсупов, 2006, с. 186]. Традиция сакланып, язылмаска да мөмкин: күңлемең (كوڭامنگ) күзене [Юсупов, 2006, с. 190]. Килеш кушымчасының өстендә өч нокталы *ң* (ڭ) графемасы белән генә дә бирелүе күзәтелә: изгеләрнең (ايزگولرگ) әлләрен [Фәхретдин, 1907, б. 418, Юсупов, 2006, с. 192].

Г. Кандалый шигырьләрендә дә, алдагы авторлардагы кебек, абстракт һәм конкрет мәгънәле сүзләрнең өченче төр изафә бәйләнешендәге сүзтезмә ясап, ягъни иялек килешендәге исемнең I, II, III зат тартымлы исемне ачыклап килү очрагы еш кабатлана: башыңның очыдин [Кандалый, 1988, б. 395]; икемезнең дә атымыз, кешенең сүзедин [Кандалый, 1988, б. 397]; бу ғалимләрнең эшилә [Кандалый, 1988, б. 400] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, иялек килешендәге исем иялек мөнәсәбәтен, ягъни бер предметның затка, яисә икенче предметка каравын билгелелек төсмере белән белдерә. Бу мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Г. Кандалыйның поэмаларындагы кебек үк, шигырьләрендә дә шундый ук кулланылыш күзәтелә: йөзеңнең рәүнәқе [Кандалый, 1988, б. 72]; атамның қарғышын [Кандалый, 1988, б. 75]; утның эченә [Кандалый, 1988, б. 77]; безем илнең Ирәм багы [Кандалый, 1988, б. 80]; ғыйшқың уты [Кандалый, 1988, б. 119] һ.б.

XIX гасырның икенче яртысында язылган тезмә әсәрләрдә угыз һәм кыпчак төрләнеше дип аерымлана торган килешләрнең сайланып кулланылуы, аерым авторның тулаем иҗаты, яисә аның берәр әсәре-

нең әдәби телнең кайсы варианты белән язылуын күрсәтә торган үзенчәлеге булып күтәрелә. Әмма бер үк авторның иҗатында чиратлашып файдаланылуы да күзәтелә. Г. Чокрый «Шәмгъ-эз зыйа» китабының (1883) керешен укучыга аңлаешлы булсын дип яза, иялек килеше сөйләмә формада кулланыла:آدملارننك – адәмләрнең, عالملارننك – ғалимләрнең, اوزلاريننك – үзләренең һ.б. Укымышлы кешеләр турында язылган мәдхия вә мәрсияләрендә шул ук килеш угыз төрләнешендә бирелә: ул зарифең, шәрифең [Чокрый, 1883, б. 22] һ.б. Бу әсәрдә III һәм II зат тартымлы иялек килешендәге исемнәрнең эзлекле рәвештә өченче төр изафә бәйләнешендәге сүзтезмә булып кулланылуы күзәтелә: бу дөнйаның хале [Гомәров, 2006, б. 118]; йирнең йөзене, назирларның аһе, хәзан баде, гөлең дәүране, бәһарең мәүсиме [Гомәров, 2006, б. 120] һ.б.

Г. Чокрый «Замме назыйр» китабының икенче исемен, Бакырганиның «Ахыр заман» әсәре шәрехләнгәнен истә тотып, «Заман ахыры бәйанында» дип куйган (1888). Беренче китабының текстлары белән чагыштырганда, бу хезмәтнең теле гавам аңласын дип язылганга, асылда, халыкның җанлы сөйләмендә кулланыла торган сүз һәм сүзформалар әдәбиләштерелеп, шул исәптән иялек килеше дә кыпчак тибында файдаланыла: мөэминләрнең (مومنلرنگ) уғлы-қызы, мөғаллимнең (معلمنگ) ғайбәтләрен, мөғаллимнең (معلمنگ) эче-тышы [Чокрый, 1888, б. 3] һ.б.

М. Акмулланың «Даменла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе»ндә (1892): аның (آننك) өчен, йөрәген мөғаниднең (معاندنك), [Акмулла, 1892, б. 3]; үземнең (اوزمنك) ноқсаныма, кемнең (كمنك) хале [Акмулла, 1892, б. 4]; меллалықның (ملالق نك) хаҗәте, дәртсезләрнең (دردسزلرنك) эше, халықның нәзарында (خلق نك), һиммәтленең (همتلنك) қулы, ғомре үтәр бичараның (بيچاره نك) [Акмулла, 1892, б. 5] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, М. Акмулла әсәрендә дә, алдагы авторлардагы кебек үк, иялек килеше кушымчасы алган исем III зат тартымлы исем белән, өченче төр изафә бәйләнешендә сүзтезмә тезеп кулланыла. Кушымчаның ике *нун* (ننك-) һәм نك бер *нун* (ننك-) хәрефе белән язылышы күзәтелә, транскрипцияләгәндә ике очрак та *-ның* дип бирелә.

Әйтеп үтелгән авторлардагы кебек үк, Г. Тукайның беренче шигырьләрендә дә, традиция буенча, иялек килешенең угыз формасында файдаланылуы дәвам ителә. Бу үзенчәлек иялек килеше кушымчасы алган исемнең III зат тартымлы исем белән өченче төр изафә бәйләнешендә сүзтезмә тезеп кулланылуында ачык күренә: ғолумең

бақчасында [Тукай, 1985, б. 24]; милләтең дәрденә [Тукай, 1985, б. 34]; бунларың ширбәтләре [Тукай, 1985, б. 37]; шөруғның юқлыгы [Тукай, 1985, б. 38]; миллләтнең былбыллары [Тукай, 1985, б. 41]; тәңренең лотфына [Тукай, 1985, б. 46]; суықның зәмһәрире [Тукай, 1985, б. 51]; милләтең бу хәле, ... милләтең дәрде [Тукай, 1985, б. 56]; заманың инқылабатыйнә [Тукай, 1985, б. 60] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, угыз формалары сөйләмә телгә хас булган кушымчалар белән аралашып бара.

XIX гасырда иҗат ителгән әсәрләрдә юнәлеш килешенең угыз һәм кыпчак төрләнешенә хас формалары кулланыла. Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи…» әсәрендә юнәлеш килеше кушымчасының угыз-көньяк төрләнешенә хас варианты кулланыла, ягъни тартык авазларга тәмамланган сүзләр – *-а/-ә* (ـه), сузык авазга тәмамланган сүзләр *-йа/-йә* (ـيه) кушымчасын алалар: شيخه – шәйхә, بازار ه – базара [Каргалый, 1889, б. 2], يوسفه – Йосыфа, اسرايله – Исраилә, اوزكايه – үзгәйә [Каргалый, 1889, б. 3], كشيه – кешейә, سفره يه – сөфрәйә, قرآنه – Қоръәнә, انصافه – инсафа [Каргалый, 1889, б. 4], نفسه – нәфсә [Каргалый, 1889, б. 5] һ.б.

II һәм III зат тартымлы алынмалар да, төрки-татар исемнәре дә, хәзерге әдәби телдәгечә, *-ә, -нә* кушымчасы белән күрсәтелә: бер илкеңә (ايلكنكا) дотсаң [Каргалый, 1889, б. 2]; خانه سينه – ханәсенә, اولار ينه – үләренә, آلدينه – алдына [Каргалый, 1889, б. 4] һ.б. Юнәлеш килешендәге исемнәр бу әсәрдә, хәзерге әдәби телдәге кебек үк, түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләрендә кулланыла:

1) эш-хәл билгеле бер затка, предметка, күренешкә юнәлгәндә, кыек объект мөнәсәбәтен белдерә: җаwап вирде ул шәйхә [Каргалый, 1889, б. 2], күз очыйлә Йосыфа андәк нәзар әйләде, Хақ Тәгалә әйләде Исраилә әз руй ғыйтаб [Каргалый, 1889, б. 3], инсафә килердек [Каргалый, 1889, б. 4], бер кешейә йитәчәк вар ашымыз [Каргалый, 1889, б. 4], көффәрә ягдырды афәт [Каргалый, 1889, б. 5] һ.б.;

2) эш-хәлне белдергән фигыльләр белән килгәндә, урын һәм билгеле бер хәл мөнәсәбәтен белдерә: сөфрәйә утырдылар, уйқуя варса [Каргалый, 1889, б. 5] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, кыек объект мөнәсәбәтен белдерү вазифасы күбрәк файдаланыла.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыл адәб» әсәрендә дә юнәлеш килеше кушымчаларының шундый ук тәртиптә кулланылуы күренә: Иғанәт эстәрем исемеңә (اسمنكاه) Алла, сәңә (سنكا) әлхәмделилла, ... ирүрсән җөмләйә (جمله يه) мәғбүд, безә (بز ه), сөйүеңә янсак (سوينكا يانساق) [Салихов, 1856, б. 2], уларға (ولارغه) қылдуң әнғам, бәңә (بنكا) йүкләтде,

ғазаб ғазбаныңа (عضبنكا عضاب) кылма [Салихов, 1856, б. 3]; бәңә (بنكا) андин китәргә, ... ағызына атарға, [Салихов, 1856, б. 4]; җийанның ахрына (آخرينه), капуңа ялwари кәлдем [Салихов, 1856, б. 5]; муафиқ эшләрә (موافق ايشلر ه) күндер, доғайа (دعايه) рәфығ идәргел (догага югары күтәрел [Салихов, 1856, б. 7] һ.б.

Ш. Зәкинең шигырьләрендә юнәлеш килешендәге исемнәр угызкөньяк һәм кыпчак-төньяк төрләнеше тибында кулланыла. «И дарига!» дип башлана торган шигырендә: изтирарә (اضطر ار ه) дөшмешем, қасд идәрем җаныма (جانمه), قانيمه – қаныма, وارلغمه – варлығыма, بكا – бәңа, نسنه يه – нәснәйә, سكا – сәңә, дәргяһә (در كاهه) сөрсәм башымы һ.б. Тартымлы исемнәр юнәлеш килешендә *-нә* кушымчасы белән күрсәтелә: дөшде ғамь гардәбенә (غم كردابنه), فكر ينك در ياسينه – фикеренең дәрйасына [Зәки, 1907, б. 415–416; Зәки, 2002, б. 40].

«Бән Ходаның...» дип башлана торган шигырьдә: ...гәр ғыйнайәт қылмаса ул шаһ бу ғасый бәндәгә (بنده كه), бу ләғыйнә (لعينه) Сам-у-Рөстәм һиммәтен күстәрәсе, ... кер ушал мәйдана (ميدانه), ал қулға (قولغه) тәвәккәл тыйғанны, ... изгеләрең әлләрен алыб туғры йула (يوله) варасы, ... тәрк идеб әғйәре ул тәңрейә (تكرى يه) йалwарасы һ.б. Күренгәнчә, *бәндәгә* һәм *кулга* сүзләре кыпчак төрләнешендә кулланыла, I зат тартымлы исем юнәлеш килешендә *-ә* кушымчасы ала: чуқ гөнаһ итдем бән ул Мәғбүдемә (معبو د مه) бу дөнйада. III зат тартымлы исем *-нә* кушымчасы белән кулланыла: хәзрәтенә (حضر تنه) варасы [Зәки, 1907, б. 417–418; Зәки, 2002, б. 32–33] һ.б.

Г. Кандалыйның «Сахибҗәмал» поэмасында: ...тоташлый бара йазыққа, ... андый фасиққа (فاسققه), йөрерсең тамақың туймай ки бәгзе чақда ачлыққа (آجلققه), ... балықчының тамағы ач булыр, йөрсә дә балыққа (بالققه), ... охшаб қара қалмыққа (قالمققه), ... башын қуйса ястыққа (ياصدققه), ... үбеб-қочыб да көйләсәң бер ай тулғанда тансыққа (طانسققه), ... ятырға китә аулаққа (آولاققه) [Кандалый, 1988, б. 391–395] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, Г. Кандалыйның поэмасында юнәлеш килешендә файдаланыла торган исемнәрнең фигыль белән мөнәсәбәттә, кыек объект мөнәсәбәтендә кулланылуы аңлашыла. Бу шагыйрнең шигырьләрендә юнәлеш килешенең шулай ук урын, вакыт, сәбәп, максат мөнәсәбәтен белдереп файдаланылуларын да билгеләргә мөмкин: Тубай агачына қундыр, ... сабырлық юлына күндер [Кандалый, 1988, б. 73]; ...чит илләргә, ерақ җиргә [Кандалый, 1988, б. 75]; ...җиде кат күкләргә ашды [Кандалый, 1988, б. 79]; ...киләдер илгә илләрдин, ... фәлян йиргә йитәр булсаң [Кандалый, 1988, б. 88] һ.б.

Г. Чокрыйның «Шәмгъ эз-зыя...» китабының (1883) керешендә юнәлеш килешедәге исемнәр кыпчак төрләнешендә кулланылалар: روى زمينكا – руи зәмингә, صونكعيلارغه – соңғыларға, يادغه – йадға [Чокрый, 1883, б. 3] һ.б. Әлеге үзенчәлек шагыйрьнең башка әсәрләре өчен дә хас.

М. Акмулланың «Даменла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе»ндә: Мәғанә җәваһирен қулға (قولغه) элгән, Қайнар сөткә (سوتكا) сары майны тамызған ул, чәйгә (جايغه) һәркем су алғандай, хаклықға (حقلقغه) җуллағанлар, қанча бала сөткә (سوتكه) туеп, ғоламәгә (علماغه) сәрдар булып, мөбариз мәйданына (ميد اننه) бу чыққан соң [Акмулла, 1892, б. 2]; мөселманға (مسلمانغه) қарышуға (قارش وغه) лаеқ имәс, күрә алмайлар ғаләмгә (عالمكا) фашын аның, һәр тарафға (طرفعه) [Акмулла, 1892, б. 3] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, юнәлеш килешендәге исем күбесенчә фигыль сүз төркеме белән бәйләнештә туры, кыек объект мөнәсәбәтләрен белдерә. Шуның белән бергә, бу мисалларның барысы да Даменла Шиһабетдин хәзрәтнең бөек галим-фазыйл булуын, аның гыйлем җәүһәрләренең хакыйкать гыйлеме булуын образлап тасвир итә торган чара буларак файдаланыла.

Г. Тукайның башлангыч чор иҗатында юнәлеш килешендәге исемнәр, угыз-көньяк һәм кыпчак-төньяк төрләнеше өчен хас кушымчаларны алып, түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләрендә кулланылалар:

1) урын-вакыт мәгънәсендә: ...қайда қышқа азық, ... қалаға саттылар, ... ашарға булмағач [Тукай, 1985, б. 82]; ...варсын клубә [Тукай, 1985, б. 37]; ...артқа қарасақ [Тукай, 1985, б. 40]; алға барыйқ [Тукай, 1985, б. 42] һ.б.;

2) кыек объект мәгънәсендә: ...нә дәүләт милләтә ... улды [Тукай, 1985, б. 34]; ...будыр шатлық вирән дәрдле колүбә [Тукай, 1985, б. 37]; ...ғыйлем белмәс хайваннарға без охшамыйк [Тукай, 1985, б. 42]; мәзлүмнәргә яқты, нурлы көннәр килде, инде нәүбәт без бичараларға җитә [Тукай, 1985, б. 42]; ...ғафилләргә дөнйа тардыр [Тукай, 1985, б. 43] һ.б.;

3) эзлекле рәвештә образлы тезмәләр барлыкка китерелә: Барып керик хөрриятнең қочагына, Тәрәққыйның күкләренә очмағына, Бу егетләр безне дөнйа оҗмахына, Қулдан тотып җитәклиләр, белең имди! [Тукай, 1985, б. 43]; Наданлыққа юл ачмыйқ, Ачыйқ иттифаққа йул [Тукай, 1985, б. 45] һ.б.

XIX гасырда иҗат ителгән әсәрләрдә төшем килеше угыз *(-ы, -(ы)ны)* һәм кыпчак *(-ны, -(ы)н)* төрләнешендә күрсәтелә. Ә. Карга-

лыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди « әсәрендә: тәсбих рәсмене (رسمنى), Алла исемене (اسمنى), ошбу сүзне (سوزنى), قلبمى – қальбеми, قاروننى – қарунны [Каргалый, 1889, б. 2], харбыза тохымыны (تخمنى), ناننى – наныны, мөхибләр намыны (نامنى), ايشكنى – ишекне, әнбиялəр сөннәтене (سنتنى), ديوارنى – диварны, قابونى – қапуны, аларның малыны (مالنى), مالنى – малны, قابوسين – қапусин, мәхәббәт мәйлене (ميلنى), كوزلارنكى – күзләреңи, ديدارنى – дидарыны, اغيارنى – әғйарыны, اميدونى – өмидүне, طابدوغون – табдуғун [Каргалый, 1889, б. 3] һ.б. Төшем килешендәге исемнәрнең күбесе үзләренең төп грамматик мәгънәсе белән файдаланыла, ягъни туры объект мөнәсәбәте билгелелек төсмере белән белдерелә.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыл адәб» әсәрендә: عبوديت يولين – ғабудият йулын [Салихов, 1856, б. 2]; بزلرى безләри сабит қаддәм кыл [Салихов, 1856, б. 3]; يولنى – йулны, قولونكنى – қолыңны [Салихов, 1856, б. 3] һ.б.

Г. Кандалыйның «Сахибҗәмал» поэмасында: сағышыңны (صاغشنكنى) мөдам итдем, өмидемне өзә алмай [Кандалый, 1988, б. 388]; ...йөрәгем бәғрене кисдең [Кандалый, 1988, б. 390]; ...қойма ғазиз ғомреңне йилләрдә, иман сүзен дийә белмәс, [Кандалый, 1988, б. 391]; эшләри (اشلرى) қуймай, ... башын (باشن) бер қуйса ястыққа [Кандалый, 1988, б. 393]; ...атасына килер парға [Кандалый, 1988, б. 395]; ...бер матур өчен уйқымны юғалттым, ... хыял дәрйасына баттым [Кандалый, 1988, б. 396]; ...ишетеп аңла бу сүзи, ... болардик итмәсен бези, қазандик қайната бези [Кандалый, 1988, б. 398] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, төшем килешендәге исемнәрнең күпчелеге кыпчак төрләнешендә булса да, угыз төрләнеше традициясенең дә дәвам иткәне күзәтелә.

Г. Чокрый «Шәмгъ эз-зыйа» әсәрендә III зат тартымлы исемнәрнең төшем килешен традицион язма формада бирүне кулайрак күрә: олуг газизләр үзләренең нәфесләрене (نفسلرونى), вә ғазиз җанларыны (جانلارونى), белгән ғыйлемләрене (علملارونى), ғазизләрнең исемләрене (اسملارونى) [Чокрый, 1883, б. 2] һ.б. Авторның «Замме назыйр» әсәрендә юнәлеш килеше кебек үк, төшем килеше дә кыпчак төренә хас булган кушымчалары белән кулланыла: Йирне (ايرنى) нитәк йаратдисә, күкне (كوكنى) һаман, Айны (آى نى) нитәк йаратдисә, көне (كونى) һаман, Әнбийә (انبا) мәрсийәләрне (مرسللرنى) итсәм тәмам, Андин артық тәқый ғаҗәб таңлары вар ..., Алла тийү хақ йадуны (يادونى) йад қылмағай, Вәғәз қылған ғарифләрне (عارفلارنى) йалған дигәй ..., Уғыл-қызлар олуқларны (اواوغ لانى) иза қылғай [Чокрый, 1888, б. 3] һ.б. Күренгәнчә,

бу автор иялек, төшем, юнәлеш килешләрен, күпчелек очракта, кыпчак, ягъни җанлы сөйләмә телдәге төрләнешендә куллана.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә (1892): Мәганә җәваһирен (جوا هرون) кулга элгән, фанусны (فانوسنى) кабызган ул, сары майны (ماينى) тамызган ул, әлһарул-хакаикны (انهر الحقا نقنى) агызган ул, чыкарды татлы суны (صونى) [Акмулла, 1892, б. 2]; батырларны (باطرلارنى) талдырган ул, төлке исен (ايسن) сизеп йөргән [Акмулла, 1892, б. 3, 2001, б. 11–12] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, М. Акмулланың бу әсәрендә төшем килеше кушымчасы эзлекле рәвештә хәзерге әдәби телдәге кебек *-ны/-не* белән бирелә, исемне фигыльгә ияртә, туры объект мөнәсәбәтен билгелелек төсмере белән белдерә.

Чыгыш килеше өйрәнелә торган чорда кушымчада әлифнең язылу-язылмавына һәм әлеге кушымчаның традицион уйгыр язуы үзенчәлеге булган *-дин* формасында бирелә алуына карап вариантлылык хасил итә.

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә: جهتدين – җәһәтдин, سندين – сәндин, حقدن – хакдан [Каргалый, 1889, б. 2], حددن – хәддән, آفتيدين – афәтедин, قبوسندن – капусыдин, طرفدن – тарафдан, قابودن – капудан, ايماندين – иманыдин, بندن – бәндән, سببدين – сәбәбдин, موندين – мондин [Каргалый, 1889, б. 3], ماحضردن – махәзәрдән, دنيادين – дөнйадин [Каргалый, 1889, б. 4] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, бу әсәрдә, чыгыш килеше кушымчасы *-дин* һәм әлифсез варианты белән кулланыла. Түбәндәге мәгънәләре белән файдаланыла: 1) эш яки хәлнең сәбәбен белдерә: бу җәһәтдин нәчәләр мәнкүб улыр; 2) кыек объект мөнәсәбәтен чагыштыру төсмере белән бирә: пөр бәһә улды хакы хәддин гиран, иманиндин газиз; 3) эш-хәлнең чыгыш ноктасын күрсәтә: капусиндин бер әр кәлер мәгәр, капудан килә; 4) тотрыклы тезмә хасил итә: бәндин үзгәйә һ.б.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыл адәб» әсәрендә: حضر تنكدن – хәзрәтеңдән, سندن – сәндән, هوايادين – һәвайадин [Салихов, 1865, б. 2], خدادين – ходадин, قابونكدن – капуыңдан [Салихов, 1856, б. 3] һ.б.

Ш. Зәкинең «И дәрига!...» дип башланган шигырендә: ...ул җанибдән (جانبدن), ... булалидән (بولاليدن) бире күңлемдә җәмалендән (جمالندن) әсәр, сандән (صاندن) кәчмешем, дөшдем айакдан (آياقدن), калмады һәр гиз өмидем, сәндин (سندن) үзгә кемсәдән, бәндән (بندن) разый улгыл, сәндин (سندن) үзгә кемсәйә, ошбу нәфсем афәтендән (آفتندن) гәр хәлас итсәң бәне, үзгә куркулардан (قورقولردن), аслан, зинһарым калма-

ды, сәндән (سندن) ғайре йарым қалмады [Зәки, 2002, б. 40] Мисаллардан күренгәнчә, чыгыш килешендәге барлык исемнәр дә бер генә төрле әлифсез вариантта языла, транскрипцияләнгәндә әйтелешкә туры китерелә, төрле мәгънә мөнәсәбәтен белдерә [Юсупов, 2006, с. 38–39].

Г. Кандалыйның шигырьләрендә чыгыш килеше төрле мәгънәләре белән кулланыла: 1) эш-хәлнең вакытын: Йөзеңнең рәүнәқе бетәр, Йәшендән керсә кайгыга [Кандалый, 1988, б. 72] һ.б.; 2) эш-хәлнең сәбәбен: Яна бәғрем, сула йөзем, Аwырлыклардин, ғуредән [Кандалый, 1988, б. 73]; Йөрәккә қан утырды ла сағышдин [Кандалый, 1988, б. 77]; Фирақлекдин яна бәғрем [Кандалый, 1988, б. 79] һ.б.; 3) эш-хәлнең чыгыш ноктасын: Қулыңдин эшләри куймай, Қачыйм тизрәк бу илләрдин [Кандалый, 1988, б. 75] һ.б; 4) эш-хәлнең кыек объектын: Язарға бән қаләм алдым қамышдин [Кандалый, 1988, б. 77] һ.б. Түбәндәге өзектә рифма таләбе белән төшем килешендә кулланылырга тиеш *чәй* сүзе дә чыгыш килеше кушымчасы ала: Эчәр булса бу чәйдин ул [Кандалый, 1988, б. 84]. Аерым дүртьюллыкларда төрле мәгънә белдерә торган чыгыш килешендәге исемнәр тезелеп бирелә: ...Сәбах эчрә ки йилләрдин, Киләдер илгә илләрдин, Хәбәр көтәм туғанлардин, Дәйүб сорам ки анлардин [Кандалый, 1988, б. 88]. Алдагы авторлардан аермалы буларак, биредә чыгыш килеше күпчелек очракда *-дин* кушымчасы белән күрсәтелә.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә 2981): ...Мөзмәрдә сабиқлардан (سابقلردن) чықды ғасрәт, бездән (بزدن) чықды, йәнбуғус-сәламәтдән (ينبع السلامة دن) юллар ачып, сүз кузғар ул ир кирәк йирдән (يردن), дөррәсендән (در ه سندن) қанча бала сөткә туеп, ... палванлардан (بالوانلردن) йығылыб бу күргән юк [Акмулла, 1892, б. 2]; Ул бер фазыйл ғалләмә узған табдан (طابدان), Хаззы бар дәрәҗәи ижтиһаддан (اجتذاد دان), алгы сафдан (صافدن), үтә алмайлар эзендән (ايزندن) басыб аның, китә алмайлар йулындан (يولندن) ашыб аның, һәр тарафқа сөйүлүде дәқаикдан (سيول الدقايق دان) ағызған йиме ғыйрфан, тирән йердән (تيرن يردن) [Акмулла, 1892, б. 3] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, чыгыш килеше кушымчасы әлифсез һәм әлифле вариантларда күрсәтелә, төрле мәгънә белдереп кулланыла.

Урын-вакыт килеше калын әйтелешле сүзләрдә дә, нечкә әйтелешле сүзләрдә дә бер генә төрле кушымча ала. Ә. Каргалый әсәрендә: ноқреме әлеңдә (النكده), әлемдә (المده) ике пул [Каргалый, 1889, б. 2]; Мисыр эчендә (اجنده), базарда (بازارد ه) йисә һәр кеше, هفته ده – һәфтәдә, آيد ه айда килерсә бер фәқыйрь, шәрғдә (شرعد ه) көфер улды [Каргалый,

1889, б. 3]; ...дин-дөньяда аяғым хәвари мән, ... бу эшдә тәдбиреӊ нәдер, ... башым өстендә, ... қаршысында дордилар, ... алдына қуеб [Каргалый, 1892, б. 4] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, урын-вакыт килешендәге исем, эш-хәлнеӊ урынын яки вакытын белдерә, җөмләдә хәл була, объект мәгънәсен белдерү сирәк күзәтелә.

Һ. Салиховныӊ «Китабе мәҗмәгыл адәб» әсәрендә: تلمد ه – телемдә, کو نکاد ه – күӊледә, آخرتد ه – ахирәтдә, مغفرتد ه – мәғфирәтдә [Салихов, 1865, б. 2]; اوسنومد ه – өстемдә [Салихов, 1865, б. 3] һ.б.

Ш. Зәкинеӊ «Эстәсәм галәмдә...» шигырендә: ...эстәсәм ғаләмдә, ... ат сәнеӊ астыӊдадыр, ... қарчыға қулыӊдадыр, ... җан илә иман икәүлән бер өйдә бал эчәләр [Зәки, 1907, 416]. Мисаллардан күренгәнчә, урын-вакыт килешендәге исем эш яки хәлнеӊ урынын белдерү вазифасы белән кулланыла.

Г. Кандалый шигырьләрендә әлеге килештәге исемнәр түбәндәге мәгънәләрдә кулланылалар: 1) урын мөнәсәбәтендә: ...даим мәдрәсәдә тордым [Кандалый, 1988, б. 74]; ...бу илләрдә торып калсам [б. 75]; ...бу йирдә юк бәнем қадрем [Кандалый, 1988, б. 79]; ...қамыл эчендә лапырдап, юеш балчықта чапырдап [Кандалый, 1988, б. 82]; ...йырақ йирдә [Кандалый, 1988, б. 93] һ.б.; 2) вакыт мөнәсәбәтендә: ...моӊаеладыр безгә дә, мөбарәк айлар тулғанда [Кандалый, 1988, б. 80]; ...йөретеп җәйдә дә, қышда [Кандалый, 1988, б. 83]; ...пароходлар төшкән чақда [Кандалый, 1988, б. 93] һ.б.; 3) объект мөнәсәбәтендә: бу шадлық күренә һәр сүздә [Кандалый, 1988, б. 81] һ.б.

М. Акмулланыӊ «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнеӊ мәрсиясе» әсәрендә (2981) урын-вакыт килешендәге исем: 1) эш-хәлгә карата урын мөнәсәбәтен белдерә: Қазанда ... чықды, ... хақаиқ диӊгезендә гаувас булып, ... мәйданда ул чықарды [Акмулла, 1892, б. 2]; ...баралмадым қашына аныӊ [Акмулла, 1892, б. 3]; ...үгәй ана кулында ятим қалдым, уйламаӊыз дөнйада мәргән юк диб [Акмулла, 1892, б. 4] һ.б; 2) вакыт мөнәсәбәтен ачыклый: ...қараӊғыда фанусны қабызған ул [Акмулла, 1892, б. 2]; ...бу заманда туған йуқ аӊа нәзыйр [Акмулла, 1892, б. 3]; ...бу чақда һичкем аӊа тиӊ килмәйде [Акмулла, 1892, б. 8] һ.б.; 3) кыек объект мөнәсәбәтен белдерә: ...дақаиқда мөшкел чишеп қалдырған ул, ... туған йуқ мәғрифәтүр-рижалидә мондай маһир [Акмулла, 1892, б. 3]; ...халықныӊ нәзарендә Хур күренеп [Акмулла, 1892, б. 5]; ...китабында исеме юк [Акмулла, 1892, б. 6] һ.б.

Тезмә әсәрләрдә дә баш килештәге исемнәр чәчмә әсәрләрдәге кебек күп төрле мәгънәләрдә кулланылалар, әмма һәр әсәрдә аларныӊ

аерым бер вазифада ешрак кабатлануы күзәтелә. К. Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы»нда (1868) барлык төрдәге синтаксик вазифалары (җөмләдә ия, тәмамлык, аергыч, хәбәр) һәм морфологик мөмкинлекләре (эш яки хәлнең субъекты, туры объекты, иялек һ.б. мөнәсәбәтләре) белән файдаланыла, әлеге вазифалар бу әсәрдә эзлекле рәвештә икенче төр изафә тәртибендәге тезмәләрдә чагылыш таба. Мәсәлән: 1) субъект мөнәсәбәте: Алла Тәғалә хәзрәтләре аңа бер сөекле вә мәхбүб уғыл бирде, ... Җиһан халқы аның күркәмлегенә вә җәмалына ғашыйқ иде [Насыйри, 1975, б. 221]; ...ачу уты күкрәген яндырып [Насыйри, 1975, б. 224]; ...әҗәл ширбәте эчеп [Насыйри, 1975, б. 228] һ.б.; 2) туры объект мөнәсәбәте: ...ғыйшық утына сабыры қалмыйча, ... ғыйльме һәйәт вә ғыйльме нөҗүм өйрәнмәк өчен, ... адәм сурәте нәқыш итеп тутыр, ... суғыш қораллары белән зиннәтлә [Насыйри, 1975, б. 226] һ.б. 3) бер предметның икенчесенә урын-вакыт ягыннан нисбәт ителүе: Мисыр тегүчеләре, Багдад тегүчеләре, шәһәр капкасы [Насыйри, 1975, б. 221–250]. Поэзия әсәрләрендә бу төрдәге изафәнең шактый сирәк, эзлекле рәвештә өченче төр изафәнең файдаланылуы күзәтелгән иде.

К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда (1881) да грамматик күрсәткече булмаган исемнәр барлык функцияләрдә дә кулланыла, «Кырык вәзир»дә файдаланыла торган үзенчәлек дәвам итела: ...сабақ балалары үз араларында сөйләшерләр иде, ... пиғамбәрләр вә әүлияләр қаберенә зийарәт қыла-қыла киттеләр [Насыйри, 1974, б. 209]; ...иртәгә мәғарә қапусы ачылачақтыр [Насыйри, 1974, б. 210]; ...зәйтүн мае белән қәнәғәт қылырлар иде, ... бадам мае белән қатыштырып қояшқа қуйдылар [Насыйри, 1974, б. 212] һ.б.

Шуның белән бергә, бу әсәрдә җөмләдә ия, яисә тәмамлык булып кулланыла торган баш килештәге исемнәр *вә* теркәгече белән парланып файдаланыла: ...ғыйлем вә хикмәт вә мәғрифәт арттырмақ қасды белән [Насыйри, 1974, б. 209]; ...үзендә Аллаһы Тәғалә биргән ниқадәр ғыйлем вә хикмәт, вә ниқадәр қодрәт вә қуwәт барлығын изһар қылмақ өчен [Насыйри, 1974, б. 210]; ...күп ғыйззәт вә хөрмәтләр күрсәтде [Насыйри, 1974, б. 211]; ...Әбүғалисина вә Әбелхарис хәзерләгән мәғәрәгә килделәр [Насыйри, 1974, б. 212]; ...әтрафында бүлмәләр вә сөфрәләр вә почмақларында ағар чишмәләр вә һәйбәт көтепханәләр бар иде [Насыйри, 1974, б. 212] һ.б.

К. Насыйриның фәнни һәм фәнни-дидактик хезмәтләрендә нуль формадагы исемнең ия функциясе ике төрле ысулда бирелә.

Беренчесе – автор укучысына турыдан-туры эндәшү формасында яза, бу вакытта хәбәр боерык фигыль белән бирелә: И газиз бала, агяһ бул,... [Насыйри, 1881, б. 3]; И уғыл, әгәр шағыйрь булып шиғырь әйтмәк қасд итсәң, җәһәт ит ки,... [Насыйри, 1975, б. 63] һ.б.

Икенчедән, К. Насыйри үзенең күп кенә фәнни хезмәтләрен гомуми затка мөрәҗәгать итеп яза, бу вакытта җөмләләр *мәгълүм ула ки* яки *белгел ки* формасында башлана, иярчен тәмамлык җөмләнең иясе булып нуль формадагы исем, хәбәре булып өченче зат хәбәрлек кушымчалы исем, яисә *-ды* күрсәткечле категорик үткән заман фигыле килә: Мәғлүм ула ки, тыйб дигәнемез адәмнең җисеменә гариз булган аwыруларны белмәкдән ғыйбарәтдер вә һәм ул аwыруларны дәwа қылып адәмнең бәдәнендән чыкара белмәкдән ғыйбарәтдер [Насыйри, 1893, б. 20]; Белгел ки, күкрәк 24 қабырғадан мөрәккиб бер читлекдән ғыйбарәтдер ки,... [Насыйри, 1893, б. 44] һ.б.

Шулай итеп, поэзия әсәрләрендә ия функциясендә килә торган исемнең традицион рәвештә Аллаһыга эндәшү вазифасы бу авторда киңәйтелә, ул укучыларга, персонажларга эндәшү буларак да файдаланыла башлый.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда (1887) сөйләнә торган вакыйгалар, нигездә, шушы алым белән алып барыла, әмма Ходайга ялвару белән бергә, монда бер персонаж икенчесенә дә үтенеч белдерә: ...вә диде ки, и Сәғыйд, әгәр дөнйага бала килмәгәне теләсәң, хәләл малыңдан мең акча сәдака бир, ... вә иғтиқадыңны дөрест кыл ... вә үз-үзенә әйтде ки, и бер ходаем, сәндән шундай уғыл теләдем ки, ул изгү вә ғақыллы вә қамил булғай дип, ... Тутый бу сүзләрне ишетеп, и Хуҗа Сәғыйд ... имде сәндән телим ки, мәне сатып аласән вә олуғ файдаларға ирешәсән ... Хуҗа Сәгыйд әйтде, и Тутый, гәрчә мәнем һәм күңлемдә сәңа мәел вә мәхәббәтем көчледер, ләкин ни қылмақ кәрәк... [Фәизхан,1887, б. 5] һ.б.

Т. Яхинның «Тәгълим әл-әдәб-иләл-вәләд» (1898) хезмәтендә: И уғыл, белгел ки, падишаһның итәғәте асыл дин илә сабит кәлмеш... [Яхин, 1898, б. 4]; И уғыл, падишаһға җан вә дил илә итәғәт итмәк кәрәк... [Яхин, 1898, б. 5]; И уғыл, дөнйада диянәт вә иғтибардан әфзаль хасийәте йуқдыр вә бу мақсуда ирешмәк юл вафа вә садақадыр ки... [Яхин, 1898, б. 7] һ.б.

Укучыга эндәшеп хикәяләү үзенчәлеге мәгърифәтче әдипләрнең сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә дә дәвам ителә. Мәсәлән, М. Акъегетнең «Хисаметдин менла»сында: «Н» қарйасына қайтамыз, хөрмәтле

уķучыларым [Акъегет, 1886, б. 12]; Фикереңезлә ахшам wаķытларыны тасаwыр идеңез, уķучыларым [Акъегет, 1886, б. 41]. Урыны-урыны белән әлеге эндәш сүз, җөмләнең гадәти кисәгенә әверелдерелә: Хөрмәтле укучыларымның зияенләрен арытмакдан чәкенеп, хикәямнең ул кадәр лязем улмаhн тафсыйлатыны язмыйурым [Акъегет, 1886, б. 50]. Үзеннән-үзе аңлашылганча, бу хикәядә тагын персонажлар кара-каршы сөйләшкән вакытта, берсе икенчесенә хат язган вакытта да эндәшү-мөрәҗәгать итүләр бирелә: Җаным, Хәнифә ханым! ...; Ғыйззәтлү Хисаметдин хәзрәтләре [Акъегет, 1886, б. 26].

Әлеге үзенчәлек З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә»сендә дә күзәтелә: Ғыйззәтлү уķучы, мәķтүлә мөслимә улса да, мөселманча язу язмаķ белмидер иде [Бигиев, 1991, б. 223]; ...Әхбабе ғазизем Ғабдуллин әфәнделәренә... [Бигиев, 1991, б. 248]; Әнкәем, йөрәк бәғрем,... [Бигиев, 1991, б. 249]. Күренгәнчә, мәгърифәтче әдипләр үзләренең әсәрләрендә берлек сан баш килештәге исемне укучыга эндәшү, сүз башлау функциясендә эзлекле файдалана.

Классик әдипләрнең кайберләре, аерым әсәренең ни өчен һәм ничек язылуын аңлату өчен, укучыга эндәшү формасын ике-өч битле махсус сүз башы итеп киңәйтә. Г. Исхакыйның «Кәләпүшче кыз» (1900) әсәре «Хөрмәтле уķучым! Үземнең күңелемнең йимешен сезгә тәкдим итәм», дип башлана да, иҗат эшендәге яңалык аңлатылып дәвам ителә [Исхакый, 1998, б. 50–51]. «Бай угылы»ның беренче басмасында (1903) мөкаддимә «Хөрмәтле уķучым! Җәнабеңезгә тәкдим итдекем китабым бала wаķытымда язылдығы өчен күп йирләрендә ķосурлары бардыр. Шуның өчен сездән ғаҗизанә ғафуыңызны үтенәм...», дип башлана да, бай балаларының тәрбиясендәге җитешсезлекләрне күрсәтер өчен язылуын аңлатып дәвам ителә [Исхакый, 1998, б. 113–114]. Әмма алга таба, әдәби әсәрдә берлек сан баш килештәге исемнең, Аллаһыга ялвару рәвешендәге, яисә укучыга эндәшеп сүз башлау алымы кулланылмый, ләкин авторның максатын аңлатуы рәвешендә файдаланылып, билгеле бер эволюция кичерә.

Г. Ибраһимов «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән беренче хикәясенә түбәндәге тезмә юлланы кереш итеп бирә: Ачылмасмы татарның ике күзе? Җәһаләтдән һәлак була милләт үзе. Бундан соң күренмәсме икән безгә, Мәғшуķымыз мәғәрифнең ике күзе [«Әлислах», 1907, № 2]. Ф. Әмирхан «Гарәфә кич төшемдә» дигән хикәясенең икенче басмасына (1909) «Бер-ике сүз» дигән кереш язып, беренче басмасы [«Әлислах», 1907, № 4] турында аңлатма бирә [Әмирхан,

1984, б. 6]. Әдипнең «Танымаганлыктан таныштык» хикәясендә дә, шулай ук, «Бер-ике сүз» дип, авторның максаты аңлатыла: «Монда очрый торган “мин” кәлимәсен мөхәррирнең үзеннән тәгъбир дип уйлау хата булачактыр. Хикәя язганда бу тәгъбир, гомум тарафыннан қабул ителгән бер тәгъбир булып, мөхәррирнең үз фикерен күбрәк кертер өчен истигъмаль ителәдер. Фатих». Шулай итеп, баш килеш берлек сандагы исем белән укучыга эндәшү үзенчәлегенең проза жанрында эволюция кичерүен билгеләп үтә алабыз.

Иялек, юнәлеш, төшем килешләренең угыз һәм кыпчак төрләнеше өчен хас үзенчәлекләренең сайланып кулланылуы, аерым әдипнең тулаем иҗаты яисә аның берәр әсәренең гасыр башындагы әдәби телнең кайсы варианты белән язылуын күрсәтә торган үзенчәлеге булып күтәрелә. Г. Фәезханов һәм К. Насыйри дәреслекләрендә, мисаллардан күренгәнчә, татар теленең сөйләмә формалары үрнәк итеп алына һәм аңлатыла. К. Насыйри хезмәтендә: «...имде телемездә мөбтәдә игърабындан башка өч игъраб хәрфе бардыр: *-ны* (نى-), *-га* (غه-), *-ның* (ننك-): آغاچننك – ағачның, خلفهننك – хәлфәнең, قولننك – қулның, كوزننك – күзнең, كيتابنى – китабны, قلمنى – қаләмне, شاكردكه – шәкердкә, جغفركا – җәгъфәргә, قولنى – қулны, كوزنى – күзне, قولغه – қулға, كوزكا – күзгә, مسجدده – мәсҗеддә, بازارده – базарда, قولده – қулда, كوزده – күздә», – дип аңлатыла [Әнмүзәҗ, 1895, б. 46]. Игътибар итик, мисалларда, аңлы рәвештә, нигезендә тел алды һәм тел арты сузыклары булган сүзләр махсус сайланып алына. Бу авторлар фәнни хезмәтләрендә аңлатыла торган нәзари фикерләрен, әдәби әсәрләрен язганда гамәли юнәлештә файдаланырга тырышалар.

Хәзерге әдәби телдә иялек килешенең, предметның (затның) башка предметка (затка) ия булуын белдерүе һәм тартым категориясенә мөнәсәбәттә булуы бәхәссез дип карала [Хангилдин, 1954, б. 75]. *-ның* кушымчасы белән белдерелә торган иялек килеше мәгънәсе иялек мөнәсәбәтен билгелелек төсмере белән белдерә. Сөйләмдә исә гомуми грамматик мәгънә төрле төсмерләр (предметны затка яисә предметка, хис-тойгыларны шәхескә нисбәтли һ.б.) ала. Иялек килешендәге исем, тартымлы исемне ачыклап килгәндә, аергыч була, өченче төр изафә бәйләнешендәге сүзтезмә барлыкка килә [Хисамова, 2006, б. 83]. Шуның белән бергә иялек килешендәге исемнең кайбер фигыль формаларын ачыклап килүләре дә күзәтелә [Татар грамматикасы, 2002, б. 53]. К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда (1881) бу сүз һәм сүзформалар нәкъ менә шул рәвешле кулланыла: ابو على سينا قصه سى ننك –

Әбүғалисина қыйссасының, ابوالحارث ننك – Әбелхарисның, падишаһының (بادشاهننك) қыйссасы, كنابننك – китабның [Насыйри, 1896, б. 2] һ.б. Иялек килешендәге исем тартымлы исемне ачыклап, III төр изафә бәйләнешендәге сүзтезмәләр буларак эзлекле кулланыла: Мәдхи әфәнденең китабын (افندىننك كتابن), бер адәмнең (بر آدمننك) һиммәте белән, қыйссаның мәзмунын (قصه ننك مضمونين) вә мәгънәсен (معناسىن) фәһемләү, хижрәтнең (هجرتننك) өч йөз йетмеш өченче йылында [Насыйри, 1896, б. 3]; كتابننك آخرنده – китабның ахырында, موننكزيراكلكين – моның зирәклеген, مكتبننك توشامى – мәктәбнең түшәме, صبى لقننك حكمى – сабыйлықның хөкеме, دنياننك جيتندن – дөнйаның читендән, شهرننك ايذكولرى – шәһәрнең изгеләре [Насыйри, 1896, б. 4] һ.б.

Г. Фәезхановның «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» хезмәтендә иялек килеше *мозафен иләйһи* (ияртүче сүз)] дип атала: ...кемнең? кемнекенең? сорауларына җавап булып килә торган исемнең ахырына *-ның* (-ننك) адәте тоташыр дип белдерелә [Фәизхан, 1887, б. 8]. Әлеге килештәге исемнәр биредә дә, К. Насыйри әсәрендәге кебек, кыпчак-татар төрләнешендә төрле мәгънә төсмерләре белән кулланылалар: 1) өченче төр изафә бәйләнешендәге сүзтезмәләр составында: بز زماننك ا يجنده – тиз заманның эчендә, دنيا يوزى ننك – дөнья йөзенең [Фәизхан, 1896, б. 2], اوشبو شهرننك – ошбу шәһәрнең, مالننك حسابنى – малының хисабыны, بالاننك طالعين – баланың талиғын [Фәизхан, 1896, б. 3] һ.б.; 2) бер предметның икенчесенә нисбәт ителүен белдерәләр: бу китабда зикер кылынған бәет вә шиғырьләрнең (بيت و شعرلرننك) [Фәизхан, 1896, б. 2], كل باقجوه سى ننك جاجاغينه – гөл бакчасының чәчәгенә охшаган [Фәизхан, 1896, б. 3] һ.б.; 3) предметның билгеле затка каравын ачыклыйлар: خوجه سعيدننك اوينه – Хуҗа Сәгыйднең өенә [Фәизхан, 1896, б. 3] һ.б.; 4) иялек килешендәге исем, исем фигыль белән мөнәсәбәттә, эш башкаручы субъект мәгънәсен белдереп килә: ...قارت ننك اوكراتوى – қартның үгрәтүе [Фәизхан, 1896, б. 3] һ.б.

К. Насыйри һәм Г. Фәезханов әсәрләрендәге кебек, Ә. Уразаев-Кормашиның кыйссаларында да иялек килеше *-ның* (-ننك) формасында, халкыбызның сөйләмә теленә нигезләнгән әдәби нормада төрле мәгънә төсмерләре белән кулланыла. «Кыйссаи Бүз йегет» (1874) әсәрендә: ...صورت ننك عشقى قزغه اثر ايتدى – сурәтнең қыйшықы қызға әсир итде [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 2]; قزننك عشقلعى – қызның ғыйшықлығы, بوز يكت ننك آطن – Бүз йегетнең атын, قز ننك آتا آناسى – қызның ата-анасы [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 3] һ.б. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: ...бу падишаһның (بادشا ه ننك) шәһәрдән тышра бер бақчасы (باقجه سى)

бар иде [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 2]; لوا كمسه ننك كونكلند ه – ул кемсәнең күңлендә, بر آغاج ننك يانىنه – бер ағачның янына [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 3]; زهر ه ننك عشقى – Зөһрәнең ғыйшқы, طاهرننكآغزندان – Таһирның ағызындан, үзенең (اوزىننك) гүзәллек бостанындан, زهر ه ننك محبتى – Зөһрәнең мәхәббәте [Кормаши, 1894, б. 6] һ.б.

Шуның белән белән бергә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында иске татар теленең угызлашкан вариантында язылган аерым чәчмә әсәрләрдә, иялек килешенең кыпчак төрләнеше булган *-ның* кушымчасы белән генә түгел, язма традицияне дәвам итеп, угыз төрләнешендәге *-ың* күрсәткече белән дә бирелүе күзәтелә. Бу үзенчәлек әлеге килешнең грамматик вазифаларына йогынты ясамый, фәкать авторның иске татар теленең угызлашкан варианты белән иҗат итүен күрсәтә. М. Акъегет үзенең «Хисаметдин менла» (1886) хикәясендә иялек, төшем һәм юнәлеш килешләрен, асылда, угыз-көньяк тибы төрләнешендә куллана. Иялек килешендәге исем сузыкка тәмамланса да, тартыкка тәмамланса да бер генә төрле *-ың* (نك-) күрсәткече белән бирелә, әлеге кушымча *нун* белән *кәф* кушмасы рәвешендә языла, төрле мәгънә төсмерләре белән кулланыла: 1) предметның затка яисә предметка каравын белдерә: қарйә(не)ң (قريەنك) әһалисе, қарйәсе(не)ң (قريه سينك) ханәләре, анбары вә мәхкәм сарайлары сахибе(не)ң (صاحبينك) иҗтиһадлы вә хезмәт сәүән адәм идегене күстәрүрләр иде, ... менла Хисаметдинең (حسامالدىننك) мәрхүм атасы указный менла улмыш исә дә, угылы атасы(ны)ң (آتاسينك) җәһәтенә муаффақ уламады [Акъегет, 1886, б. 2,] һ.б.; 2) иялек килешендге исем тартымлы исемне ачыклап килгәндә, өченче төр изафә бәйләнешендәге сүзтезмә рәвешендә кулланыла: әһалисе(не)ң (اهاليسى نك) мәғыйшәт өчен хезмәте игенчелекдер [Акъегет, 1886, б. 2]; ...карт менла(ны)ң (منلانك) буш сүзләренә инанмаеп [Татар мәгърифәтчелек, 1979, б. 52] һ.б.; 3) иялек килешендәге исем, исем фигыль белән бергә килгәндә, эш башкаручы мәгънәсен белдерә: ...менланың кердегене белеп [Татар мәгърифәтчелек, 1979, б. 51] һ.б.

Сирәк очракта увуляр борын тартыгы [ң] *кәф* белән генә дә бирелә: адәм(не)ң (آدمك) халенә [Акъегет, 1886, б. 6]; аның (آنك) назарында [Акъегет, 1886, б. 14]; сәилиләр(не)ң (سايليلرک) нәфәкаләрене [Акъегет, 1886, 16]; دشمانك – дошманың [Акъегет, 1886, б. 18]; بونلروك – бонларуң һ.б. [Акъегет, 1886, б. 30]. Бер-ике урында *менланың* сүзе (منلاننك) кыпчак төрләнешендә язылган [Акъегет, 1886, б. 36].

Мисаллардан аңлашылганча, әлеге әсәрдә иялек килеше кушымчасына хас булган вариантлылык *-ң* аффиксының ничек, ягъни нинди

графема белән ясалуына нигезләнә. Шуның белән бергә, сүз ахырында [-ң] һәм [-к] тартыкларының бер төрле язылуы сәбәпле кайбер сүзләрне төрлечә укырга мөмкин була. Текстны транскрипцияләгәндә исә, иялек килеше кушымчасы хәзерге татар әдәби телендәге кебек, сингармонизм законына буйсынып бирелә. Шунысы игътибарга лаек, бер генә *кәф* белән язылган очраклар әле *-уың* булып, әле *-ың, -ең* булып күчерелә: бер адәмнең хәленә [Татар мәгърифәтчелек, 1979, б. 48]; ятим саилләрең нәфәкаләрене [Татар мәгърифәтчелек, 1979, б. 54] һ.б.

З. Бигиевның сәнгатьле прозасында иялек килеше кушымчасы төрле әсәрендә төрлечә языла. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887) әсәрендә сүзнең нигезе тартыкка тәмамланса да, сузыкка тәмамланса да иялек килеше кушымчасы *-ның* (ننك-) булып языла: خاتوننك – хатынның [Бигиев, 1887, б. 6], خادمهننك – хәдимәнең, ايرننك – ирнең [Бигиев, 1887, б. 7], قاتلننك – қатилнең [Бигиев, 1887, б. 8], زليجاننك – Зөләйханың [Бигиев, 1887, б. 8], سزننك – сезнең [Бигиев, 1887, б. 11], بولمهننك – бүлмәнең, توتاشننك – туташның [Бигиев, 1887, б. 33], بایننك – байның [Бигиев, 1887, б. 34] һ.б.

«Гөнаһе кәбаир» (1890) романында иялек килеше кушымчасы сузыкка тәмамланган сүзләргә – ике *нун* белән (ننك-), тартыкка тәмамланса – *нун* һәм *кәф* белән (نك-) языла: اشحاصنك – әшхаснең [Бигиев, 1887, б. 2], اللهننك – Алланың [Бигиев, 1887, б. 2], آتاسیننك – атасының [Бигиев, 1887, б. 2], اهلایسیننك – әһалисенең [Бигиев, 1887, б. 2], ناكسنك – Нәкәснең [Бигиев, 1887, б. 2], حضرتنك – хәзрәтнең [Бигиев, 1887, б. 5], اولانلارنك – уланларның [Бигиев, 1887, б. 7], على باباننك – Ғали бабаның [Бигиев, 1887, б. 8], ماهروينك – Маһруйның [б. 8], ملاننك – мелланың [Бигиев, 1887, б. 9], مدرسهننك – мәдрәсәнең [Бигиев, 1887, б. 10], آغييفنك – Агиевның [Бигиев, 1887, б. 11], آننك – аның [Бигиев, 1887, б. 18]. Искәрмәләр дәшактый сирәк: بایننك – байның [Бигиев, 1887, б. 9], باينك – бай(н)ың [Бигиев, 1890, б. 12] һ.б.

«Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксаниядә сәфәр)» язмасында иялек килеше, кайбер чиратлашулар белән, сузыкка тәмамланган сүзләрдә *нун* һәм *кәф* (نك-), тартыкка тәмамланганнарда өч нокталы *кәф* графемасы (ڭ-) белән күрсәтелә: حضرتلرينك – хәзрәтләренең [Бигиев, 1908, б. 1], يولچيلارڭ – йулчыларның [Бигиев, 1908, б. 2], پاراحودڭ – пароходың [Бигиев, 1908, б. 2], قارندشلرمزك – қарендәшләремезең [Бигиев, 1908, б. 3], نهرينڭ – нәһеренең [Бигиев, 1908, б. 3], تاريخك – тарихың [Бигиев, 1908, б. 3], منصورڭ – Мансурың [Бигиев, 1908, б. 3], عربلرڭ – ғарәбләрең [Бигиев, 1908, б. 4], دولتينك – дәүләтенең [Бигиев,

1908, б. 4], سامانیلرڭ – Саманиларың [Бигиев, 1908, б. 5], آنلارڭ – анларың [Бигиев, 1908, б. 5], رئیسلرینڭ – рәисләренең [Бигиев, 1908, б. 6], تموچینڭ – Тимучиның [Бигиев, 1908, 6], روسیانڭ – Русийәнең [Бигиев, 1908, б. 6] һ.б.

Ф. Кәриминең сәнгатьле прозасында иялек килеше кушымчасы беренче «Мәҗлес гыйльми»дә кабул ителгән тәртиптә, ягъни *нун* һәм өстенә өч нокта куелган *кәф* (نڭ-) белән белдерелә. «Бер шәкерд илә бер студент» (1899) әсәрендә: июнь айының (آینڭ), قومپانیه‌سنڭ – компанийәсенең, پاراحودنڭ – пароходның, کانتورنڭ – кантурың, جیلاننڭ – җиләннең, آلارنڭ – аларның, برسیننك – берсенең, ایکنچی‌سنك – икенчесенең [Кәрими, 1899, б. 2]. Мисаллардан күренгәнчә, *кәф* графемасы өч нокта белән языла, бик сирәк очракта, -*(ы)ң* кушымчасы, аерым *кәф* белән ноктасыз белдерелә: хәзрәтең (حضرتك) киявенә, хәзрәтнең (حضرتنك) йанына, хәзрәтнең (حضرتنك) чырайы [Кәрими, 1899, б. 9] һ.б. Сүз ахырында сузык яисә тартык булу исәпкә алынмый.

«Җиһангир мәхдүмнең ауыл мәктәбендә укуы» (1900) хикәясендә дә иялек килешенең язылуында шундый ук тәртип саклана: حضرتنک – хәзрәтнең, حضرتنڭ, جهانکیرینك – Җиһангиренең, حضرتنك – хәзрәтнең [Кәрими, 1900, б. 2–3]. Әмма монда, -*(ы)ң* кушымчасындагы *кәф*нең бер үк өч сүздә өч төрле язылуы күренә, транскрипциядә өчесе дә -*ның* формасында бирелә [Татар мәгърифәтчелек... 1979, б. 230–245].

Ф. Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902) «Тәрҗемен» газетасы кебек гомумтөрки халык укысын дип язылганга, угыз элементлары бик актив, шул исәптән, иялек килеше кушымчасы да угыз төрләнеше тибында бирелә: тартыкка тәмамланган сүзләргә язылган -*(ы)ң* (ڭ-, ک-, ك-) аффиксы, III зат тартымлы сузыкка тәмамланган сүзләргә -*ының* (نڭ-, نک-) аффиксы ялгана: ...кидәҗәк йулың (یولڭ) вә кидәҗәге wақытың (وقتڭ) озынлығына нәзарән иҗра иделмешдер. Хәзердә иске заманларда улдығы кеби киделәҗәк йулың (یولڭ) озынлығына бақарақ хәзерлек күрмәк лязем дәгел, бәлки киделәҗәк мәмләкәтең (مملکتڭ) мәдәният вә ғомрәненә бақарақ хәзерлек күрмәк ляземдер [Кәрими, 1902, б. 2]; ...йалғыз сәйәхең (سیاحک) күз ишарәтенә, кидәчәкемез мәмләкәтләрең (مملکتلرك) харитасына [Кәрими, 1902, б. 3]; Шакир әфәнденең (افندینک), буның (بونك) эчендә [Кәрими, 1902, б. 3]; افندینك – әфәнденең [Кәрими, 1902, б. 4]; Хөсәеновлар мәдрәсәсенең (مدرسه سنك), قله سنك – кәлисәнең, Сорбон дарелфөнүнең (دارالفنوننك) асыл тәдрисе [б. 4] [ 1902, б. 5] һ.б.

Ф. Кәриминең гомумтөрки юнәлешендә язылган фәнни хезмәтләрендә дә иялек килеше угыз төрләнешендә файдаланыла. Шулай итеп, бер үк әдипнең, әсәрен кайсы укучыны күздә тотып язуына карап, угыз һәм кыпчак төрләнешенә караган сүзформаларны, шул исәптән иялек килеше кушымчалы исемнәрне дә сайлап куллануы күренә.

Әлеге үзенчәлек Р. Фәхретдиннең иҗатында да ачык чагыла. Галимнең «Тәрбияле ана», «Тәрбияле бала» (1898) кебек «ачык ана телемездә йазылган» нәсыйхәтләрендә иялек килеше кушымчасы өч нокталы *кәф* (ڭ) рәвешендә язылa: тәрбияле аналарның (آنلارنڭ) балалары, тәрбияле аналар дөнйаның (دنيانڭ) иң қадерле, иң хөрмәтле кемсәләредер, ахирәтдә һәм оҗмахның (اجماحنڭ) йулбашчыларыдыр [Фәхретдин, 1898, б. 3]. بالالارنڭ – балаларның, بالالارىنڭ – балаларының, آنلارنڭ – анларның, قزلرينڭ – қызларының, اوقونڭ – уқуның [Фәхретдин, 1898, б. 16], тәрбияле баланың (بالانڭ) бит, қул сөртә торган йаулығы [Фәхретдин, 1898, б. 3], اوزيننڭ – үзенең [Фәхретдин, 1898, б. 4], آناسينڭ – анасының [Фәхретдин, 1898, б. 5], بالانڭ – баланың [Фәхретдин, 1898, б. 7], معلملرنڭ – мөғәллимләренең [Фәхретдин, 1898, б. 6], كشيلرنڭ – кешеләрнең [Фәхретдин, 1898, б. 13] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, килеш кушымчасының бирелешендә төрлечә язылыш күзәтелми.

Р. Фәхретдиннең «Тәрбияле хатын» (1899) китабында, югарыда искә алынган ике әсәре белән чагыштырганда, алынмалар күбрәк кулланыла, [г], [к], [ң] авазлары да, алдагы хезмәтләрендәге кебек үк, ныклы бер тәртиптә бирелә. Иялек килеше кушымчасы тартыкка тәмамланган сүзләрдә дә, сузыкка тәмамланганнарында да, алдагы әсәрләрендәге кебек үк, бер генә төрле *-(ы)ң* (ڭ-) рәвешендә язылa, *кәф* өч нокталы итеп күрсәтелә: Алла Тәғалә хәзрәте үзенең (اوزينڭ) олуғлығыны белдермәк өчен ..., хисабсыз мәхлүқатның (مخلوقاتنڭ), бу ғаләмнең (عالمنڭ), اوزلرينڭ – үзләренең, حضرنلرىنڭ الله تعالى – Алла Тәгалә хәзрәтләренең, آدملرنڭ – адәмләрнең [Фәхретдин, 1899, б. 2], һәр икесенең (ايكيسينڭ) [Фәхретдин, 1899, б. 3], كمسهنڭ – кемсәнәнең, غاوغانڭ – ғауғаның, اوزلرينڭ – үзләренең [Фәхретдин, 1899, б. 3].

Әдипнең «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1899) романында иялек килешендәге исемнәр алдагы әсәрләрендәге тәртипне саклап кулланыла: Казан виләйәте губернасының (عوبرناسىنڭ), لرنڭ – бунларның, Казан елгасының (ايلعهسينڭ), كوڭ لمنك – күңелемнең [Фәхретдин, 1899, б. 4], سنك – сәнең [Фәхретдин, 1899, б. 5], бу мөбәрәк (سوزلرڭ) сүзләрең, شاكردلرنڭ – шәкердләрнең [Фәхретдин, 1899, б. 6] һ.б. Мәгънә төсмерләренә килгәндә, аларның барысына да мисалларны табарга мөмкин,

ләкин кайберләре ешрак кабатлана. Аерым очракларда иялек килешендәге исемнең, үзе бәйләнгән тартымлы исемнән, җөмләнең башка кисәкләре белән бүленеп кулланылуы күренә.

Р. Фәхретдин «Әсма яки гамәл вә җәза» (1903) хикәясендә традицион язма сүз һәм сүзформаларны ешрак куллана, шул исәптән, иялек килешендәге сүзләр дә, нигездә, угыз төрләнешендә файдаланыла, килеш кушымчасының ясалышы да үзгәрә. Сузык авазлардан соң ул *нун* белән *кәф* (نك-), тартыклардан соң ялгыз *кәф* (ك-) рәвешендә бирелә: Башкорт исемең (اسمينك), بونلرك – бунларың, قوملرك – қаумләрең [Фәхретдин, 1903, б. 3], دنيانك – дөнйаның, بلغار تركلرينك – Болгар төрекләренең [Фәхретдин, 1903, б. 6] һ.б.

Иялек килешенең төрле әсәрендә төрлечә формалашуы әдипнең «Асар» (1904–1909), «Нәсыйхәт. Олуглар вә бөекләр өчен. Гыйлем әхлякдан тукызынчы җөзьә» (1911) һ.б. күпсанлы хезмәтләрендә дә дәвам итеЛә.

Г. Гафуров-Чыгтай, Ш. Мөхәммәдев, З. Һади кебек мәгърифәтчеләрнең, шулай ук Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал М. Гафури, Г. Камал һ.б. классик әдипләрнең әсәрләре текстларында иялек килеше, асылда, җанлы сөйләмә формасы белән кулланыла.

Балалар өчен язылган әдәбиятта да иялек килеше, нигездә, шушы тәртиптә, ягъни *-ның* кушымчасы алган халәттә генә кулланыла, ягъни *нун* белән *кәф* кушмасы буларак күрсәтелә. Балалар өчен төзелгән «Белек» китабында (1872): Бер қарт мылтықчының (ملط قچىننك), شيرچقننك – шыйырчықның, مالاىننك – малайның, آلارننك – аларның, كتابلارننک – китабларның [Радлов, 1872, б. 8], حلقننك – халықның [Радлов, 1872, б. 9] һ.б.

Т. Яхинның «Сабый вә сабыялар өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр» (1902) китабында: چاىننك – җәйнең, اولنننك – үләннең, سكرتكهننك – сикерткәннең, سزننك – сезнең, بورىننك – бүренең, پسناكننك – песнәкнең [Яхин, 1902, б. 8] һ.б. С. Рахманколыйның «Монтазам кыйраәт китабы»нда (1912): қартның, мәченең [Рахманколый, 1912, б. 5], ялқаулықның, үземнең [Рахманколый, 1912, б. 6], куписнең [Рахманколый, 1912, б. 7], қарғаның [Рахманколый, 1912, б. 9] һ.б.

Дини-дидактик эчтәлектәге хезмәтләрдә иялек килеше кушымчасы *ның* (نڭ-), ягъни кыпчак формасында кулланыла. М.С. Иманколыйның «Салятыйн ислам» (1909) хезмәтендә: Ислам хәлифәләре вә падишаһларының (پاديشاهلرينڭ) әхwәлене ..., милләтемезнең (ملتمزنڭ) андаен китабка ихтыяҗы ...; كتابنڭ – китабның [Иманколый, 1909, б. 3],

صحابەلرنك – сахәбәләрнең, كرامنك – кәрәмнең [Иманколый, 1909, б. 4], Мәккә (شهرينك) шәһәренең, هجرتنك – Һиҗрәтнең [Иманколый, 1909, б. 6] һ.б.

Беренче драмаларда һәм классик әдипләрнең чәчмә әсәрләрендә, нигездә, традицион формалар юк дәрәҗәсендә генә файдаланыла.

Шулай итеп, иялек килеше кушымчасының бирелешендә, беренчедән, кыпчак һәм угыз төрләнешенә, икенчедән, графемалар язылышына караган графо-орфографик вариантларның кулланылуы һәм төрле авторда төрлечә файдаланылуы күренә. Әмма бу үзенчәлек, иялек килешендәге исемнең морфологик табигатенә дә, синтаксик вазифасына да тәэсир итми. Иялек килешендәге исем, нинди генә кушымча алса да, икенче исем белән бәйләнештә, бер предметның затка, яисә икенче предметка каравын белдерә.

Юнәлеш килеше хәзерге татар әдәби телендә *-га/-гә, -ка/-кә,* I һәм II зат тартымлы исемнәргә *-а/-ә,* III зат тартымлы исемнәргә *-на/-нә* кушымчалары ялганып ясала. Ул исемне фигыльгә, сыйфатка, рәвешкә ияртә, эшнең урынга, вакытка һ.б.ларга юнәлешен, яисә эшнең сәбәп, максатын белдерә. Эш-хәлнең затка, предметка, күренешкә юнәлеше белдерелгәндә кыек объект мөнәсәбәтендә була, бәйлекләр белән аныклана, тотрыклы сүзтезмәләр, тезмә сүзләр составында кулланыла.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында җанлы сөйләмә тел берәмлекләре әдәбиләштерелеп язылган әсәрләрдә дә әлеге кушымчалар үзләренең барлык вазифалары белән файдаланыла. Шуның белән бергә, күрсәтелгән вакытта иҗат ителгән әсәрләрдә юнәлеш килешенең угыз төрләнешенә хас булган күрсәткечләре белән файдаланылуы күзәтелә. Бу очракта, тартыкка тәмамланган сүзләргә *-а/-ә* (ا- ,ه-), сузыкка тәмамланганнарга *-йа/-йә* (يه-) кушымчасы ялгана. Димәк, күрсәтелгән вакытта юнәлеш килешендәге исем, кыпчак һәм угыз төрләнешенә нигезләнгән ике тел нормасына хас булган формаларда хәрәкәттә була, әлеге нигездә графо-орфографик яссылыкта вариантлылык хасил була. Әлеге мәсьәлә аның грамматик вазифаларына берничек тә тәэсир итми, авторның иске татар теленең җәдиди госманлы (угызлашкан) варианты белән иҗат итүен генә аңлата, аерым авторларның кайбер әсәрләрендә, кыпчак һәм угыз төрләнеше чиратлашып файдаланыла.

К. Насыйриның сәнгатьле прозасында юнәлеш килешендәге исемнәр кыпчак төрләнеше тибында кулланыла. Нигезендә тел алды сузыгы булган һәм яңгырау, борын, сонор тартыкларга тәмамланган

сүзләр *-гә/-кә* (کا-) кушымчасы ала. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: اوكرانماكا– үгрәнмәгә, علمكا – ғыйлемгә, حكمتكا – хикмәткә [Насыйри, 8981, б. 4], شهركا – шәһәргә, بزكا – безгә, سزلركا – сезләргә,, اجكا – әҗәлгә, كاعزكا – кәғәзгә, مغارهكا – мәғәрәгә [Насыйри, 8981, б. 6] һ.б. Нигезендә тел арты сузыгы булса, сузыкка, һәм сонорларга тәмамланган сүзләр *-га* (غه-) кушымчасы ала: بالاغه – балаға [Насыйри, 8981, б. 4], دنياغه – дөнйаға [Насыйри, 8981, б. 6], اورتاغه – уртаға, اللهغه – Аллаға [Насыйри, 8981, б. 7], بالالارغه – балаларға [Насыйри, 8981, б. 8] һ.б. Нигезендә тел арты сузыгы булган һәм саңгырау, тирән тел арты тартыгына тәмамланган сүзләргә *-ка* (قه-) кушымчасы ялгана: حلقه – халыкқа [Насыйри, 8981, б. 5], اول طرفقه بو طرفقه – ул тарафқа бу тарафқа [Насыйри, 8981, б. 5] һ.б.

I һәм II зат тартымлы исемнәргә *-а/-ә* (ا- ,ه-) кушымчасы ялгана: حجرهمه – хөжрәмә, الديمه – алдыма, احتيارمه – ихтыярыма [Насыйри,1898, б. 12]; كولنكا – қулыңа [Насыйри,1898, б. 27] һ.б.

Шул ук затлардагы күплектәге исемнәрдә: جناب علايهلرنكزكا – җәнәбе ғалийәләреңезгә [Насыйри,1898, б. 28] һ.б.

III зат тартымлы исемнәрдә: журганы астына (آستينه) [Насыйри, 1898, б. 4], مصر شهرينه – Мисыр шәһәренә [Насыйри, 1898, б. 8], كونكلنه – күңеленә [Насыйри, 1898, б. 8], هربرسينه – һәрберсенә [Насыйри, 1898, б. 8], آياغنه – айағына, اورننه – урынына [Насыйри, 1898, б. 10], يورطنه – падишаһ йортына [Насыйри, 1898, б. 11], حضورينه – хозурына [Насыйри, 1898, б. 13] һ.б.

Бу килеш К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда (1881) түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләрендә файдаланыла: 1) исемне фигыльгә ияртеп, эшнең билгеле бер урынга, яисә вакытка юнәлүен белдерә: игез ике бала дөнйаға килеп, ... бу ике бала дүртәр яшенә җиткәч [Насыйри, 1974, б. 208]; ...һәр көн өйләгәчә дәрес биреп [Насыйри, 1974, б. 209]; ...шәһәргә барып җиттеләр [Насыйри, 1974, б. 209] һ.б.; 2) кыек объект мөнәсәбәтен белдерә: ...ғыйлем вә әдәб үгрәнмәгә хәлфәгә бирделәр [Насыйри, 1974, б. 208]; ...балалар белән уенға чығар иде [Насыйри, 1974, б. 209]; ...зирәк балаға ..., хикмәткә хилафтыр [Насыйри, 1974, б. 209]; ...халыкқа мәғлүм итмәктән максуд ни нәрсәдер [Насыйри, 1974, б. 210] һ.б.

К. Насыйриның фәнни хезмәтләрендә дә юнәлеш килеше кушымчалары, нигездә, кыпчак төрләнешендә бирелә. «Әхляк рисаләсе»ндә (1881): بالالارغه– балаларға, حلقلارغه – холықларға, بلماكانلركا – белмәгәнләргә, آدمكا – адәмгә [Насыйри, 1881, б. 2–3], آتاسينه – атасына, анасына

(آناسینه) вә остазына (اوستاذینه) хөрмәт итмәк [Насыйри, 1881, б. 6] һ.б. «Мәнафигъ әгъза вә кануны сыйххәт»тә: ساعتچیکا – сәғәтчегә, آدمکا – адәмгә, سویاككا – сөйәккә, بدنکا – бәдәнгә, کوزکا – күзгә [Насыйри, 1893, б. 42] һ.б. «Истыйляхате гыйльме Һәндәсә»дә (1895): هر نرسه‌که – һәр нәрсәгә [Насыйри, 1893, б. 3], نرسه‌کا – нәрсәгә [Насыйри, 1895, б. 3], کاغزکا – кәғәзгә [Насыйри, 1895, б. 4] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, бу әсәрләрдә юнәлеш килешендәге исемнәрнең, асылда, кыек объект мөнәсәбәтен белдереп кулланылуы аңлашыла.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә дә (1879) фигыль белән бәйләнгән юнәлеш килешедәге исемнәр: 1) эш-хәлнең урын-вакытка юнәлүен белдереп кулланылалар: бақчаға килеп, бақчаға керделәр, бер ағачның янына килделәр [Татар әдәбияты, 1957, б. 287] һ.б.; 2) кыек объект вазифасы белән ешрак кабатлануы күзәтелә: қайқулары қуанычқа алмашыныр иде, хәкимнәргә вә табипларға сансыз алтын сарыф қылып, бу дәрвишкә мең алтын биреп, қаләмен падишаһқа сонып, қаләмне дәрвишкә бирделәр [Кормаши, 1894, б. 3–4] һ.б.; 3) юнәлеш килешендәге исем белән тотрыклы сүзтезмәләре хасил була: сүзгә килеп [Татар әдәбияты, 1957, б. 287], ғаҗәпкә қалып [Татар әдәбияты, 1957, б. 289], көннән-көнгә артып [Татар әдәбияты, 1957, б. 293] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда: Қазан виләйәтемездәге қулланыла торған Тутыйнамә китабын ғосманлы төрекләре telendә күрүб вә ул телне безнең халқымызға (خلقمز غه) аңлаwы мөшкел булғанлықдан һәммә дәрд әһелләре укуб файдалансунлар өчен мәзкүр қосманлы төрекләре телендән үз татар телемезгә (تلمزکا) тәрҗемә қылдым [Фәизхан, 1896, б. 2]. Китерелгән өзектә кулланылган юнәлеш килешендәге исемнәрнең язылышыннан күренгәнчә, Г. Фәезхановның да сәнгатьле әсәрен халыкчан сүзформаларны әдәбиләштереп язуы аңлашыла.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» (1886) әсәрендә юнәлеш килеше кушымчасы угыз-көньяк төрләнеше тибында кулланыла. Тартыкка тәмамланган сүзләргә *-а/-ә* (ه-) кушымчасы ялгана: شهرلره – шәһәрләрә, کبی‌لره – кебиләрә [Акъегет, 1886, б. 2], زمانلره – заманлара, نونه – Нунә, صبی‌لره – сабыйлара, جاهله – җаһилә, بشقه‌لره – башқалара [Акъегет, 1886, б. 3], شهره шәһәрә, قاره – қара, سزه – сезә [Акъегет, 1886, б. 7] һ.б. Әлеге контекстта *җегет* сүзе кыпчак төрләнешендә бирелә: Бу йекерме биш йәшлек җегеткә (جیکتکا) тә ғаҗәбләнерсең [Акъегет, 1886, б. 4].

Сузыкка тәмамланган сүзләр юнәлеш килешендә *-йа/-йә* (ـيه-) аффиксы белән формалаша: ملايه – менлайа [Акъегет, 1886, б. 3], بلايه – бәлайа [Акъегет, 1886, б. 5], چانايه – чанайа [Акъегет, 1886, б. 7], ايجارەيه – иҗарәйә [Акъегет, 1886, б. 12], قاپويه – қапуйа, قريەيه – қарийәйә, پوليسەيه – пулисәйә [Акъегет, 1886, б. 16] һ.б.

Әсәрдә юнәлеш килешендәге исем үзе үти ала торган барлык вазифалары белән файдаланыла: 1) урын-вакыт мәнәсәбәтен белдерә: суға юл чықарыр, башқа шәһәрләрә дә ағылырлар [Акъегет, 1886, б. 2]; ԝатаны «Н»ға қайтты, китереңез бәнем үз мәдрәсәмә (مدرسەمه) [Акъегет, 1886, б. 3]; қапуйа туғры варып [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48]; шәһәрә юлланды, бер тағa менәр икән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50]; ...постоялый дворға, ягъни гавам мөсәфирханәсенә (مسافرخانەسينه) төшде [Акъегет, 1886, б. 9]; сарай тарафына бақып [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51]; шәһәргә чыгып, кенә мөсафирханәя қайтды [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51] һ.б.;

2) кыек объект мөнәсәбәтен белдерә: йөзенә бақсаң, җегеткә тәгәҗҗепләнерсең [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; тирән фикерә талдығы беленер, күңлемезә мәрхәмәт кәлер, бер миллион адәмә – бер милләтә мәрхәмәтемез юкдыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48]; ...менлаларға ағыз ачмаға да вирмәз [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 49]; нәфесемә (نفسمه) табиғ улып қыза бақтым [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51]; җөмләсенә (جملەسنه) мөсаԝи мәхәббәтең [Акъегет, 1886, б. 11]; менла күбрәк укыган бер шәкерденә (شاكردينه) [Акъегет, 1886, б. 15]; ...сүзләренә (سوزلرينه) чыдамаеп болай диде [Акъегет, 1886, б. 16] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, бу әдипнең әсәрендә юнәлеш килешендәге исемнәрнең, асылда, ике вазифасының эзлекле кулланылуы күренә.

3. Бигиевның сәнгатьле прозасында һәр ике төрләнешкә караган юнәлеш килеше кушымчалары параллель рәвештә чиратлаштырып кулланыла дип әйтергә мөмкин. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә»дә (1887): نومرغه – нумиргә, تومرلر غه – нумирләргә, تومر اجينه – нумир эченә, нумирәйә. Соңгы форма персонаж сөйләме буларак бирелгән урыннарда ешрак кабатлана, ... нумирәйә кердүкемдә бу хатынны бу кәйфийәтдә күреп, бик хәүфләндем [Бигиев, 1889, б. 5]; Бүген ақшам сәкез сәғәтдә Ғабдуллин нумирләрендә 2 нче нумирәйә кәрәм боерып кәләсез [Бигиев, 1889, б. 6] һ.б.

Кайсыбер сүзләр, киресенчә, авторның үз сөйләмендә – угыз төрләнешендә, ә персонажлар сөйләмендә – кыпчак формасында

киләләр: Сезләрә дә, хөрмәтлү уқучыларым, Мусаның ниндәләйен адәм идегене белдерәйем [Бигиев, 1887, б. 9]; Менә бу мәктүбне мәкътүлә Зөләйха хәле хәйатында сезгә язмыш, Сезгә бу эшдә бер нәрсә дә зарар улмас, Муса исемле кешегә язылдуғындан безгә булуы лязем түгел, Шубинның сезгә бундаен хезмәт илә кәлүвене қаен атаңыз Әхмәди абзый беләмү? [Бигиев, 1991, б. 226] һ.б.

Кайбер сүзләр фәкать көньяк төрләнешендә генә бирелә. Мәсәлән, *әфәнде* сүзе бер-бер артлы кабатланган вакытта да *әфәндейә* формасында гына кулланыла: Муса әфәндейә Ниғмәтулла әфәндейә абза буладыр ...Ниғмәтулла әфәнде Муса әфәндейә, Ғабденнасыр әфәнде Муса әфәндейә, дөшен Ниғмәтулла әфәндейә бу тарика сөйлидүр һ.б. *Ғарәбәйә* сүзе дә шул рәвешчә бер генә формада төрләнгән килеш файдаланыла.

*Зөләйха* сүзенә фәкать угыз телләренә хас булган, ә *Шубин* белән *Андреев* сүзләренә кыпчак телләренә хас булган кушымчалар гына ялгана: Зөләйхайа мәктүб язған идем, мәрхүмә Зөләйхайа, ләкин Шубинға, Андреевқа. Бер үк сүзләр ике төрле формада бирелгәндә, угыз традициясе авторның мәрхәмәтен белдерә булса кирәк: Ниғмәтулла әфәнде ивгә қайтып кәлде [Бигиев, 1991, б. 224]. Ләкин: Мәрхүмә Зөләйхайә: бән сәңа йәрен-иртәгә меңң рублһ ақча кәлтерермен, ивеңезә қайтырсыз, – дидегемдә... [Бигиев, 1991, б. 230].

*Суд, магазин, следователь* кебек сүзләргә *-га* аффиксы, ә *заграница, хикәямез, хәбесханә* сүзләренә *-а* аффиксы гына ялганып бара.

Әдипнең «Гөнаһе кәбаир» (1890) романында юнәлеш килеше, рәттән дип әйтерлек көньяк төрләнешендә кулланыла: бишекдән қаберә (قبره) кадәр, حيكايه مزه – хикәйәмезә, قريه يه – карьйәйә, سهرلره – шәһәрләрә, يرلره – йирләрә, امامله – имамлара, ике хатына (خاتونه) зәүҗ, вә биш балайа (بالايه) атадыр [Бигиев, 1890, б. 2] һ.б. *Мәдрәсә* сүзе бер-бер артлы ике формада кулланыла: уғлымызны Қазанға мәдрәсәгә уқытырға йебәрәмез [Бигиев, 1890, б. 4], мәдрәсәйә озатмага кәлмешләр [Бигиев, 1890, б. 5]. Ялгызлык исемнәре, гадәттә, *-га* аффиксы белән бирелә: Қазанға, Ғабделғафурға, Ғабделхақға, Яғқубқа һ.б. Әмма берничә мәртәбә *Қазана* формасы да бар, Маһруй, Җиһангир исемнәре, нигездә, *-а* кушымчасы гына ала: Қазана кәлеп йитделәр. Җиһангирә сабақ үгрәдеп [Бигиев, 1890, б. 9], Маһруйә хитабән [Бигиев, 1890, б. 25], Мостафайа карап, Әхмәдийә хитабән [Бигиев, 1890, б. 14] һ.б. Әлеге әсәрнең күп кенә урыннарында юнәлеш килеше кушымчасының мәгълүм ике төре нинди дә булса система саклап чиратлашалар дип әйтеп булмый.

З. Бигиевның «Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» сәяхәтнамәсендә кулланылган юнәлеш килешендәге исемнәр, иялек килешендәге кебек үк, нигездә, угыз төрләнешендә генә кулланылалар: Қалач нам мәнзилә юлландым, безләрә, орайа буддилек динене, шәһәрә, миладийәйә қадәр, билйәде исламийәйә, Бохарайа, тиҗарәтә, низамә, әсайыша, голүмә мәйел иранилар, сәнәйә кадәр, дөнйайа килеп, кабиләйә рәис улмыш, сәнәдән сәнәйә, тәхте солтанәтә җөлүс итмеш иде, Урта Асияйә һөҗүм итмеш, [Бигиев, 1908, б. 3 ] һ.б.

Ф. Кәрими һәм Р. Фәхретдин әсәрләрендә, юнәлеш килеше кушымчасының төре, иялек килешендәге кебек үк, шул әсәрләрнең кемгә багышланып язылуына бәйле.

Ф. Кәриминең сәнгатьле прозасында юнәлеш килешендәге исемнәр кыпчак төрләнешендә киләләр. «Җиһангир мәхдүмнең...» хикәясендә: сарыфқа (صرفقه) төшәргә [Кәрими, 1900, б. 2], آشقه – ашқа, مخدوکه – мәхдүмгә, مکتبکه – мәктәпкә [Кәрими, 1900, б. 3] һ.б. «Бер шәкерд илә бер студент» хикәясендә: چسطايغه – Чистайға, ضور پالاسلرغه – зур паласларға, باراخدقه – пароходқа, һичбер نرسه که – нәрсәгә [Кәрими, 1899, б. 2–3] һ.б. Угыз формасының, аерым персонажның укыганлыгын-белемлелеген сурәтләү чарасы буларак, ягъни югары стиль элементы итеп тә файдалануы күзәтелә. Мәсәлән, вакыйганы сөйләп баручы ишан хәзрәте белән сөйләшкәндә болай ди: Без хәзергә чикле күргән, уқыған китапларымыздан аңладығымыза күрә, иман вә исламны кием белән булмый, калеб белән була ... дип беләдер идек [Кәрими, 1899, б. 6]. Биредә *аңладығымыза* формасы, юморга төрелеп, ишан хәзрәткә яраргa тырышу булып аңлашыла.

Ф. Кәриминең сәнгатьле чәчмә әсәрләре кебек, татар укучысына дип язылган мәкаләләрендә дә иялек килеше кебек үк, юнәлеш килеше дә халыкның җанлы сөйләмендәгечә бирелә. Мәсәлән, «Рус милләтчелеге» мәкаләсендә: Русларда соң wақытларда сонғый сурәтдә артдырырга тырышыла торган «миллият хисе» хисенең хөлясасы: Русияне ялңыз православның русларға махсус итеп, һәммә инородецларға қырын қарау, анларға мөсбәт хоқуқ бирмәү, анларны үгәй бала итеп қараудан ғыйбарәтдер [Вакыт, 1910, 4 февраль].

Язучының гомумтөрки укучысы да укысын һәм аңласын дип язылган хезмәтләрендә юнәлеш килеше угыз төрләнешендә кулланыла. «Аурупа сәһхатнамәсе»ндә: сәфәрә (سفره) чықаздан әүвәл, یرلره – йирләрә, бу мәмләкәтләрә (مملکتلره) кидеб гизмәк өчен, ақча вә мәғәрифдән башқа шәйә (شيه) чуқ ихтыйаҗ йуқдыр. Артык нәрсәләрне

тулдырыб багажа (باغاژه) вирмәк өчен бер сандык алдық. Оренбургтан хәрәкәтә (حركته) қарар виреб, ... ахшам өсте кидән поезда (بويزده) утырмақ өчен вокзала (واقزاله) вардык. ... вагна (واغونه) йирләшдердек. Парижа (باريژه) вардыкда, ... қалебә (قلبه) дөрлү фикерләр киләйүр, өч айлык сәйәхатә (سياحته) киделәйүр, ... һәр икемез тәфәккерә (تفكره) талдық, Аурупайа (اوروبايه) китәйүрмез [Кәрими, 1902, б. 2–4] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Тәрбияле ана», «Тәрбияле бала» (1898) кебек, «ачык ана телемездә йазылган» дини-дидактик хезмәтләрендә юнәлеш килешендәге исемнәр кыпчак төрләнешендә кулланыла: Барча кешеләрне дөнйаға (دنياغه) китерүчеләр аналардыр, ... Тәрбияле бала дөнйада җанға (جانغه) шадлық вә ахирәтдә йөзгә (يوزگه ) ақлық китерүр, ... шунларны сезгә (سزگه ) белдерәбез, кешеләр торыб беткән соң йоқлаб йатқан балаға (بالاغه) һөнәрсез, ғарсез, йалқау диярләр [Фәхретдин, 1898, б. 2–3] Айақ үзәрендә ашаб йөргән кешенең икмәк ԝалчықлары йиргә (ايرگه) төшәр [Фәхретдин, 1898, б. 4] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, юнәлеш килеше кушымчалары *-га* (-غه), *-гә* (-گه), *-кә* (-كه) рәвешендә, өч төрле графо-орфографик вариантта файдаланыла.

Р. Фәхретдиннең «Асар» (1904) хезмәтендә юнәлеш килеше кушымчасы, нигездә, угыз формасында бирелә: Асыллары Малмыж мөсафатында Салавыч карйәсендән улыб җидди улан Туқай бу тарафа һиҗрәт итмеш иде. ... Хат йазудан мәғзурмыз, үз телемезне кешейә фәһемләтә алмаймыз. Дәфтәр сани ғанәйә сорабсыз, безем қулымыза дөшкәне йуқ. Пулә күб мохтаҗ улмасағыз бер-ике тыйлләлек җамә йәки гәйре анлара муафиқ зат йибәрелсә ғаҗәб булыр. Безем халемез үзеңезә мәғлүм, дин кимегәне йуқ, артадыр. Атамыз бай һәм улса фәқыйрә шулчақлы нәрсә йибәрелгәне йуқ ... Ғасәлдән анлара һәм тәнәԝел қылдырасыз, мәғзур. Суфиларың даирләре қулларына мал дөшсә, ишанѕна һәммәсене вирер, ... мәхдүмләрә вә сәгыйтеңезә муафиқ вирерсез [Фәхретдин, 1904, б. 77–88].

Р. Фәхретдиннең «Нәсыйхәт. Олуглар вә бөекләр өчен» (1911) хезмәтендә дә юнәлеш килешенең һәр ике формасы чиратлашып кулланыла: …иргә (ايرگه ) вармақ улдығыңызда, гүзәллегендән элек һөнәрене сораңыз вә үзеңезә (اوزڭزه) тиңдәш уланларны ихтыяр әйләңез [Фәхретдин, 1911, б. 3–4]; Хәйәле, әдәбле, ғафиф улыңыз, ирләреңезә (ايرلرڭز ه) гүзәл мөғамәлә әйләңез, ... аның рөхсәтендән башқа һич кемне йаныңыза (يانڭز ه) чақырмаңыз ... Замана мәшәқәтләренә қаршы тормақда ирләреңезә ярдәм идеңез [Фәхретдин, 1911, б. 5]; Ачулы йөзле улмаңыз. Ачу ғаләмәтләре илә һич кемгә (كمگه)

күренмәңез, ачу wақытында сөйләшмәңез, хосуса башқалара (باشقەلره) җаwаб вирмәкдән сақланыңыз, анлара (آنلار ه) асла йалан сөйләмәңез [Фәхретдин, 1911, б. 5]; Җәнаб Аллаhә (جناب للهه) доға идеңез [б. 6] h.б.

Классик әдипләрнең беренче әсәрләрендә үк, юнәлеш килешендәге исем сөйләмә телгә хас булганча, мәгърифәтчеләр файдаланган кушымча белән кулланыла. Г. Исхакыйның «Бай угылы» әсәрендә: кәғәзгә (کاغدگه) төшене йазыб йибәрә иде, дөнйаға (دنیاغه) киләчәк иде, ванныга (ۋاننغه ده) да утыртқанлар, мунчаға (مونجه غه) да керткәнләр, ... бала hаман дөнйаға (دنیا غه) килми иле [Исхакый, 1910, б. 143] h.б.

Г. Ибраhимовның «Зәки шәкерднең мәдрәсәдән куылуы»: балаларға (بالالرغه) уйнарға җайсызлый башлады, мәдрәсәгә (مدرسه گه) илтеп ташларға [Әлислах, 1907, б. 11]; мәдрәсәгә (مدرسه گه) барырға кирәк, мәдрәсәгә җыйылу [Әлислах, 1907, б. 11]; шәhәргә (شهرگه) барған адәмләрдән [Әлислах, 1907, б. 12],тәрилкәгә (تریلکه گه) язып утыра [Әлислах, 1907, б. 13] h.б.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: өстәлгә (اوسته لگه) таратылып куелган [Әлислах, 1907, б. 12]; чәчләргә (جه ج لرگه) қадалған чәчкәләр шикелле, қызға (قزغه) ишарәт итде [Әлислах, 1907, б. 14]; ғомуми күренешкә (کورنشکه) трагический халәт бирә иде [Әлислах, 1907, б. 16] h.б.

Юнәлеш килеше турында сөйләгәндә, тартымлы исемнәрнең бу килештә эзлекле файдаланылуын да әйтү зарур, әмма бу төрләнештә I hәм II зат тартымлы исемнәрнең *-а/-ә* (ه-), III зат тартымлы исемнәрнең *-на/-нә* (نه-) кушымчасы алып, эзлекле рәвештә бер төрле генә язылышта булуы сәбәgле, әлеге мәсьәләгә махсус тукталмадык.

Шулай итеп, юнәлеш килешенә хас булган әдәби норма вариантлылыгы да, иялек килешендәге кебек үк, бер яктан, гомумтөрки чордан ук килә торган язма традицияләрнең җанлы сөйләм үзенчәлекләре белән чиратлаша алуына, ягъни угыз hәм кыпчак телләре мөнәсәбәтенә, икенчедән, кайбер график билгеләрнең төрлечә язылуына нигезләнә.

Төшем килеше хәзерге әдәби телдә *-ны/-не,* III зат тартымлы исемнәргә *-ын/-ен/-н* кушымчасы ярдәмендә ясала, исемне фигыльгә ияртә, җөмләдә туры объектны белдерә [Татар морфологиясе, 2002, б. 54; Хисамова, 2006, б. 87]. Татар халкының сөйләмә теленә якын итеп язылган әсәрләрдә кулланыла торган төшем килешендәге исемнәр, асылда, әлеге кушымчалар белән күрсәтелә. Шуның белән бергә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында иҗат итүче әдипләр аерым әсәрләрендә угыз төрләнешенә хас булган аффиксларны да

файдаланалар. Бу вакытта тартык авазларга тәмамлана торган сүзләр *-ы,* сузыкка тәмамланучылар *-йы,* III зат тартымлы исемнәр *-ыны* кушымчалары ала.

Татар халкының сөйләмә телендә кулланыла торган сүз һәм сүзформаларны әдәбиләштереп язылган әсәрләр дигәндә, К. Насыйри иҗаты истә тотыла. Аның сәнгатьле прозасында файдаланыла торган исемнәр кыпчак төрләнеше тибында күрсәтелә, барлык сүзләргә дә төшем килешендә *-ны* (نی-) аффиксы кушыла, III зат тартымлы исемнәр *-н* (ن-) кушымчасын ала. «Әбүгалисина кыйссасы»нда (1882): ошбу китабны (کتابنی) [Насыйри, 1898, б. 2]; بو قصەنی – бу қыйссаны, әфәндедәнең китабын (کتابن), مضمونن қыйссаның мәзмунын вә мәгънәсен (معناسین), عبارسین – гыйбарәсен [Насыйри, 1898, б. 3]; қылны (قلنی) қырыққа йарыр иде, моның зирәклеген (زیراکلکین), جهیاننی – җиһанны, معارەنی – мәгарәне [Насыйри, 1898, б. 4]; ...бу аwазны (آوازنی), ул китабны (کتابنی) [Насыйри, 1898, б. 5]; қуwәт вә қодрәтен (قدرتسن) күргәч, қалган гомерен (عمرین), کتابلاین – китабларын, бер генә хәрефен (حرفن) [Насыйри, 1898, б. 6] һ.б.

К. Насыйриның фәнни хезмәтләрендә дә төшем килешенең кулланылышы шушы тәртиптә бара. Мәсәлән «Әхляк рисаләсе»ндә: изге холық белән явыз холықны (خلقنی) белмәк, آدمنی – адәмне, балалар ақны-қараны (آقنی قارانی), йахшы вә йаман нәрсәләрне (نرسەلرنی), تربیەنی – тәрбияне, дөнйаны (دنیانی), барчамызны йуқдан бар итеб йаратучы бер Алладыр [Насыйри, 1881, б. 2–3] һ.б.

«Әнмүзәҗ»дә: Бәс, Һәр качан телнең кавагыйде сарфийәсен (صرفیەسین) вә қавагыйде нәхүийәсен (نحویەسین) бәйан қылмасдан мөқәддәм уқу вә йазу қагыйдәсен (قاعدەسین) [Насыйри, 1895, б. 3]. Имде биззарур ошбу өч хәрефне (حرفنی) ун мәхрәҗгә тәүзиг қыламыз [Насыйри, 1895, б. 3] һ.б. Әлеге үзенчәлек қагыйдәләшерелә [Насыйри, 1895, б. 75].

К. Насыйри әсәрләрендәге кебек үк, Ә. Уразаев-Кормашиның кыйссаларында төшем килеше эзлекле рәвештә кыпчак төрләнеше тибында килә. «Кыйссаи Бүз йегет»тә: Алла әмере бар булса, дидареңезне (دیدارنکزنی) күрергә [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 2] һ.б. Аерым очракларда угыз төрләнешендәге исемнәр дә күзәтелә: табиблары килтерүр ирде [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 3].

«Кыйссаи Таһир илә Зөһрә»дә: Ходай тәгәлә морадыңны бирсен, ул дәрвишне (درویشنی) күргәч, نیتمنی – ниятемне [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 3], гыйльме рәмелне (علم رملنی) яхшы беләмен [Уразаев-

Кормаши, 1894, б. 3], қаләмне (قلمنی) қулына алыб, бақчаны әйләнеп эзләделәр [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 4], китабны (کتابنی) язмақ кирәк, Зөһрәне (زهره نی) шелтәләде [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 6] һ.б. К. Насыйри текстларыннан аермалы буларак, әлеге кыйссада III зат тартымлы исемнәр *-(ы)ны* кушымчасы белән кулланыла: Бу дәрвишкә мең алтын биреп, доғасыны (دعاسونی) алыйм, исемене (اسمونی) Зөһрә қушды, исемене Таһир қуйдылар, Зөһрәнең доғасыны (دعاسونی) қабул қылып, кәндүләрене (کندیلرونی) назға чигеп, дәрдмәнд йегетләрне харап итәләр [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 7] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда төшем килешендәге исемнәр кыпчак төрләнеше өчен хас кушымчалар белән кулланыла: تواریخلرنی – тәварихларны [Фәизхан, 1896, б. 2], آثار غریبه نی – асар гарәбияне, کتابنی – китабыны, کتابن – китабын [1896, б. 2], доғасы қабул булған кешене (کشىنى), аның исемене (اسمنی), خاتونی – хатуны, طوی امرلرین – туй әмерләрен, دنیانی – дөнйаны [Фәизхан, 1896, б. 3], барча дустларыны (دوستلرینی) йыйыб мәҗлес йасаб [Фәизхан, 1896, б. 3] һ.б.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәре (1886) иске татар теленең угызлашкан вариантында язылa. Төшем килешендәге исемнәр угыз төрләнеше тибында кулланыла: тартык авазга тәмамланган сүзләргә *-ы/-е* (ی-), сузыкка тәмамланса, *-йы/-йи* (یی-), III зат тартымлы исемнәргә *-ыны/-ене* (ینی-) кушымчасы ялгана: حکایه‌مزی – хикәйәмезе [Акъегет, 1886, б. 2], منلایی – менлайы, بالالارنکزد – балаларыңызы [Акъегет, 1886, б. 3], تفسیری – тәфсире, صحیفه‌یی – сәхифәйе [Акъегет, 1886, б. 4], ислам қардәшләрене (قرداشلرینی) [Акъегет, 1886, б. 7], җомға намазыны (نمازونی) [Акъегет, 1886, б. 7], بو یولی – бу йулы [Акъегет, 1886, б. 8], йегетләре (یکتلرد) чуқ бақмыйдыр иде, ышпалерлары (اشپلایرلرد) йармаға кызы (قزی) мәҗбүр итде [Акъегет, 1886, б. 11], سوزلرونی – сүзләрене, یستو نمازینی – йәстү намазыны [Акъегет, 1886, б. 11], یرونی – йирене [Акъегет, 1886, б. 12] һ.б. Кайбер чиратлашулар да күзәтелә. Мәсәлән: байырақ кешеләрне җәлеб итәр иде [Акъегет, 1886, б. 9], байны тәғзим итсәң [Акъегет, 1886, б. 14], Хәнифә туташны йитде [Акъегет, 1886, б. 20] кебек җөмләләрдә төшем килешендәге сүзләр кыпчак тибы төрләнешенең кушымчасы белән бирелә, яки чиратлаша.

З. Бигиевның сәнгатьле прозасында төшем килешендәге исемнәр һәр ике төрләнешкә хас булган кушымчалар белән кулланылалар. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә: حکایه مزی – хикәямезе [Бигиев, 1887, б. 2]; صودینی سلیدواتیلنی کوته لر – судьяны, следовательне көтәләр,

әхwәлене, нумирәсене, хәдимәне, нумир ишегене, хатынны, ишекне, үз-үземне, бу сүзләрне [Бигиев, 1887, б. 6]; қыяфәтене-төсене, сәламләремезне, мәктүбне [Бигиев, 1887, б. 7] һ.б.

«Гөнаһе кәбаир» романында да бу килеш шул ук тәртиптә бирелә: атасының исемене (اسمنی), Нәкәснең адыны (آدنی), қарйәнең дә адыны (آدنی), [Бигиев, 1890, б. 2]; намазы (نمازی) тиз тәмам қылды, бу йегетләрне (یکتلرنی)[ Бигиев, 1890, б. 3]; биш wакыт намазы мәсҗедә кәлеб [Бигиев, 1890, б. 4]; киләсе җомға намазын [Бигиев, 1890, б. 5]; сабах намазын [Бигиев, 1890, б. 5] һ.б.

Ф. Кәрими белән Р. Фәхретдин әсәрләрендә төшем килеше, иялек һәм юнәлеш килешләре кебек үк, текстның кемгә, кайсы адресатка багышланган булуына карап, кыпчак һәм угыз кушымчалары белән кулланыла. Ф. Кәриминең сәнгатьле прозасы өчен, нигездә, җанлы сөйләмә формалары хас. Мәсәлән, «Бер шәкерт илә бер студент» хикәясендә (1899): Мин бу тапларны (تاپلارنی) қоймақ ашағанда тамған май таплары булса кирәк дип исәпләдем, ... һәм дә бик ашығып аларны (آلارنی) узып киткән вакытда, ... Сезне (سزنی)белмим һ.б; әмма: نرسه‌لریمی – нәрсәләреме [Кәрими 1899, б. 6].

III зат тартымлы исемнәр, нигездә, традицион формада киләләләр: نرسه‌لرنی – нәрсәләрене, қулларыны бағлап, кешенең өстене-башыны [Кәрими, 1899, б. 6]; ат қазылығыны [Кәрими, 1899, б. 7]; қызыны кияүгә биргән [Кәрими, 1899, б. 7], кәғәзләрене [Кәрими, 1899, б. 7] һ.б. «Җиһангир мәхдүм...» (1898) хикәясендә дә төшем килешендәге исемнәр шушы тәртиптә кулланыла: بالانی – баланы, علم نحونی – ғыйльме нәхүне, мәктәбне (مکتبنی) ихата иткән, ғыйлемне (علمنی) күбрәк таратасы килә, бәғзе йылларны (یللرنی), شکردلرنی [Кәрими, 1898, б. 5] һ.б.

Бу әсәрдә III зат тартымлы исемнәр эзлекле рәвештә традицион формада киләләр: уғылыны (اوغلنی) пәк яхшы уқытмақчы була, درس کتابلرینی – дәрес китабларыны, Йосыф вә Бәдәвам китабларыны, әткәсенең биргән сабағыны, атасының қаләм вә қара саwытыны, мужикларның балаларыны уқытыр өчен, мәдрәсәнең әхwәлене, балаларның уқу тәртибене [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 230] һ.б.

Ф. Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә (1902) төшем килешендәге исемнәр фәкать угыз формасында гына кулланылалар: Артық нәрсәләре тулдырыб багаҗа вирмәк өчен, ... Сәфәремез мөбарәк улсын дийә бер-беремезе (بر برمزی) хәйерләдек, ... йирләре (یرلری) биззат кидеб күрмәк, хәл вә мәғишәтләрене (معیشتلرینی), ... дүрт бең сәнәлек

асари қадимә вә тарихийәйе (تاریخیه یی) вә өчәр миллион җилд китаблары (کتابلری) [Кәрими, 1902, б. 6] һ.б.

Р. Фәхретдиннең барлык әсәрләрендә дә III зат тартымлы исемнәр традицион язма формада кулланыла. «Тәрбияле ана» да (1898): Аналарның хезмәтләрене (خدمتلرنی) йазыб бетерерлек, тел илән сүзләб бәйан кылырлык дәгелдер. Алма, әфлисун, лимун ағачларыны (اغاجلرنی) қараб үсдергән бағчачыларны (باغجه جیلرنی) мәдех идәләр, ушандак йахшы балалар үсдергән, йитешдергән аналарны (آنالرنی) һәм мәдех идәдер [Фәхретдин, 1898, б. 3] һ.б.

«Тәрбияле хатын» (1899) да: Аллаһы Тәғәлә хәзрәте үзенең олуғлығыны (الغلغنی) белдермәк өчен, ошбу ғәләмне (عالمنی) йаратдырыб, хисабсыз мәхлүқатының арасында инсанларыны (انسانلرنی) ғақыл илә башқалардан айырым итмешдер, نکاح تعمتنی – никях ниғмәтене [Фәхретдин, 1899, б. 3]; Тәрбияле хатынлар үзләренең иғтиқадларыны бозықтотмақдан қамил иғтибар илә сақларлар [Фәхретдин, 1899, б. 5] һ.б.

«Сәлимә, яки Гыйффәт» романында (1899): қулыны тотыб үбдем [Фәхретдин, 1899, б. 6]; ата вә анам қаберләрене зыярәт идәчәк улдым [Фәхретдин, 1899, б. 7]. Бунча йыллар суыны эчдекем вә нигъмәтене йийдекем вә һаwасыны суладығым Қазанны ташлап [Фәхретдин, 1899, б. 8]; қурай даwышларыны, көтүчеләрнең чыбырқы шартлатуларыны, чаwыб барған юлчыларның қыңғырау даwышларыны, сандуғач сайрауларыны дыңлаб... [Фәхретдин, 1899, б. 9] һ.б.

«Әсма, яки Гамәл вә җәза» романында (1903): ғомерене ахмақлар ғадәте үзәрә, фәна ғәдәтләрене, Ғаббас мелланың холқыны, ислам балаларыны, мәғишәтене, әлифбаның исемләрене, баланың башыны [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 312] һ.б.

Мәгълум булганча, III заттагы тартымлы исемнәрнең традицион карлук-төрки һәм угыз-төрки формасы төшем килешендәге билгелелекнең икенчел күрсәткече булып тора [Киекбаев, 1966, б. 59]. Төшем килешенең шушы формасы XX гасыр башы татар әдәби теленең барлык жанр-стильләрендә дә бик актив кулланыла.

Әлеге үзенчәлек классик әдипләр иҗатында дәвам ителә, әмма һәр әдипнең әсәрләрендә ул берникадәр үзенчәлерәк вазифа башкара. Г. Исхакыйның сәнгатьле прозасында әлеге форма, гадәти тел берәмлеге буларак, рәттән тезелеп бара, ә кайберләрендә бөтенләй дә күренми. Г. Исхакый үзенең «Бай угылы» (1910) повестендә III заттагы тартымлы исемнәрнең традицион формасын гына куллана: мәхәллә хәзрәте дә зур кәғәзгә төшене (توشیتی) һәм тәғбирене (تعبیریتی)

язып йибәрә иде; ... Қарчықлар да қулларыннан килгән хезмәтләрене (خدمتلريتى) итүдә иделәр [Исхакый, 1910, б. 163]. Бикәнең бу хәлене (حالينى) ..., йөзләренә бөркеделәр, күзене (كوزيتى) ачды [Исхакый, 1910, б. 164] وزلرينك خدمتلرينى سويله ديلر – үзләренең хезмәтләрене сөйләделәр [Исхакый, 1910, б. 165]; ...Фатыйх байның бөтен йортыны (يورطينى) гөрләтде... [Исхакый, 1910, б. 165] һ.б. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1904) публицистик повестенда III зат тартымлы исемнәрнең традицион формадагы кулланылышы файдаланылмый. «Тормышмы бу?» әсәрендә (1911) әлеге форма традицион язылышта эзлекле рәвештә тезелеп бара: Аларның йөзләрене, күзләрене, қашларыны, керфекләрене, аwызларыны, иреннәрене, билләрене, күкрәкләрене җентекләп карыйм [Исхакый, 1999, б. 34]. Исемнәр кебек үк, исем фигыльләрнең дә төшем килешендә традицион кушымча белән эзлекле кулланылуы күзәтелә: аwылларның йануларыны (يانولرينى), атларның үлүләрене (اولولرينى), әйберләр сатуларыны (صاتولريتى) сөйләп иске хатирәләрене яңарта торған ағайлар [Исхакый, 1911, б. 16]; шәриғәтдән аерылмауларыны (آيرلماولنتى), анларның изелүләрене (ايزلولرنى) сөйләдем [Исхакый, 1911, б. 21]; Бунлар барысы да җанлы-җансыз хайваннар, анларның тиреләрене (تيريلرينى), анларның йонларыны (يونلرنى), тулаларыны (طولالرينى), ... ақчаларыны (آقچه لرينى) китерәләр [Исхакый, 1911, б. 23–24] һ.б. Шушы ук үзенчәлек, ягъни III зат тартымлы исемнәр һәм исем фигыльләрнең бер үк кушымча алып эзлекле рәвештә файдаланылуы «Сөннәтче бабай» (1912) хикәясендә, «Мулла бабай» романында да (1912) дәвам ителә. III зат тартымлы исемнәрнең *-ыны* формасы белән эзлекле кулланылышы авторның билгеле бер ритмны саклау, вакыйгаларны тасвирлау чарасы буларак файдалануын аңлата.

Ф. Әмирханның сәнгатьле прозасында да төшем килешендәге исемнәр *-ны/-не* кушымчасы ала, I заттан язылган «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә, I зат тартымлы исемнең яисә исем фигыльнең төшем килешендә кулланылуы күзәтелә: ғаетләрне күрүемне телиләр иде [Әмирхан, 1984, б. 8]; сабырымны җуеп [Әмирхан, 1984, б. 14]; башымны қуеп [Әмирхан, 1984, б. 16] һ.б. III заттагы тартымлы исемнәрдә традицион форманың кулланылышы төрле әсәрдә төрле дәрәҗәдә чагылыш таба. Әдипнең хикәяләрендә ул сөйләмә формада бирелә: халыққа урыннарын ишғаль итәргә [Әмирхан, 1984, б. 12], тыңлаучыларның йоқлаған вә онытылған хисләрен уятты [Әмирхан, 1984, б. 13], алған хиссиятләрен [Әмирхан, 1984, б. 14], мәсҗед халқының йоқысын [Әмирхан, 1984, б. 15], татар ғомерен [Әмирхан, 1984,

б. 17] һ.б. Традицион *-ыны* формасы сирәк күренә: хәләл иренең кулыны [Әмирхан, 1984, б. 19]. «Фәтхулла хәзрәт» әсәрендә әлеге форма рәттән тезелеп бара: татар мулласының қыланышыны, сурәтене күрергә, иске вәғәз китапларыны, «Дин вә мәғишәт» журналыны, иң қабахәт яқларыны, әүвәлге сүзене сөйләп [Әмирхан, 1985, б. 7–10] һ.б. Авторның «Хәят» повестенда (1911) III зат тартымлы исемнәрнең традицион язылышы бөтенләй кулланылмый диярлек, биредә сөйләмә форма өстенлек итә: чәчләрен тарағанда [Әмирхан, 1985, б. 120]; йөзенең өч чирек өлешен [Әмирхан, 1985, б. 124]; белемсез тойғысын [Әмирхан, 1985, б. 127] һ.б. Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, Ф. Әмирханның III заттагы тартымлы исемнәрнең язылышын ничек итеп файдаланылуына, ягъни язма традициянең саклануына, яисә сөйләмдәгечә кулланылуына карап, хикәяләүнең ритмы үзгәрүе аңлашыла.

Г. Ибраһимовның беренче хикәяләрендә III зат тартымлы исемнәренең язылышы традициягә нигезләнә. «Зәки шәкерт...»тә (1907): үзенең барып торачақ мәдрәсәсене, адәмләрнең бик яхшы киемләрене, мәдрәсәнең һәр төрле урынларыны, Зәки шәкертнең мәхдүмлек хиссиятене нәзары игътибарда тотып, атасы үзенең шәхси эшләрене вә Зәкинең кирәкләрене бетерде, икмәк төсене, йаңа килгән бичара йәшләргә қыла торган вәхшәтләрене дә күрә башлады [Ибраһимов, 1974, б. 400] һ.б. «Гыйшык корбаннары»нда: Сәғыйднең йөрәк маены ашый иде, аның йөрәгене парә-парә йасый иде, аның алсу йөзләрене, озын керфекләрене, ... ағызыны, аллы-гөлле нурлы йаңақларыны, ... нечкә кулларыны, ап-ақ симез беләкләрене, нечкә билләрене, ... аның мәләк кебек қыланышларыны, ... моңлы, ләтафәтле сүзләрене [Ибраһимов, 1974, б. 447] һ.б. «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» хикәясендә (1909) автор тартымлы исемнең сөйләмә вариантын куллана: бүлмәгә кереп, нәрсәләрен куеп, дошманлар аларның исемен генә ишетсә дә, мәктәп китабарын син вөҗүдкә китерден [Ибраһимов, 1974, б. 473] һ.б.

Шулай итеп, III зат тартымлы исемнәрнең традицион *-ыны* кушымчасы белән кулланылуы XX йөзнең беренче чирегенә кадәр язылган әсәрләргә кадәр дәвам итә, әмма төрле авторда төрле максат белән, төрле дәрәҗәдә файдаланыла.

Чыгыш килеше хәзерге әдәби телдә *-дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән* кушымчаларын ала, исемне фигыльгә, сыйфат һәм рәвешкә ияртә, III зат тартымлы исемнәре *-ннан/-ннән* күрсәткече белән кулланыла [Татар грамматикасы, 2002, б. 54; Хисамова, 2006, б. 88]. XIX гасыр

ахыры – XX гасыр башы татар әдәби телендә язылган әсәрләрдә бу килештәге исемнәр, хәзерге татар әдәбиятыннан аермалы буларак, *-дан/-дән* кушымчасы белән языла. Әлифнең язылу-язылмавына һәм әлеге кушымчаның традицион уйгыр язуы үзенчәлеге саналган *-дин* формасында бирелә алуына карап, иске татар теленә хас булган графо-орфографик вариантлылык барлыкка килә. Ләкин ул килешнең грамматик вазифаларына тәэсир итми. Килеш кушымчасының төрлечә файдаланылуы һәр авторның язма традициягә нинди мөнәсәбәттә булуына бәйле була.

К. Насыйриның барлык жанрда язылган әсәрләрендә дә калын сузыклы нигезгә әлифле, нечкә сузыклы нигезгә әлифсез кушымча ялгана. «Әбүгалисина кыйссасы»нда чыгыш килешендәге исем үзе бәйләнгән фигыль белән түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләрендә файдаланыла: 1) Эш-хәрәкәтнең чыгыш ноктасы белдерелә: ...бер ата бер анадан (بر آنادان) ике игез бала дөнйаға килеп [Насыйри, 1898, б. 3]; дөнйадан (دنیادان) күчте, йирдән (یردن) вә күкдән (کوکدن) хисапсыз ғаскәр җыеп, ике тарафдан (طرفدان) сафлар тартылып [Насыйри, 1898, б. 5]; ...Фисагурис عسکرندن гаскәрендән [б. 210]; ...مغارهدن мәғәрәдән чыктылар [Насыйри, 1898, б. 7]; һәр тарафдан (طرفدان) [Насыйри, 1898, б. 8] һ.б.; 2) кыек объект мөнәсәбәтендә: ...төрле фәнләрдән (فنلردن) дәрес бирер иде, олуғрак шәкердләрендән (شاکردلرندن) бәғзесе әйтер иде [Насыйри, 1898, б. 4]; вә вилаять халқындан (حلقنداذ) алыр [Насыйри, 1898, б. 6]; күңлемездәге шөбһәдән (شبههدن) [Насыйри, 1898, б. 10]; ғайре хәммәмнардан һәзар мәртәбә артық иде [Насыйри, 1974, б. 215] һ.б. «Әхляк рисаләсе»ндә (1881): خلقدان – халықдан, حیواندان – хайwандан, کسیلردن – кешеләрдән, کتابدان – китабдан, فعللردن – фиғыльләрдән [Насыйри, 1881, б.2–3]. «Мәнафигъ әгъза вә кануны сыйххат» тә (1893): ашаған тәғәмдән (طعامدان) тәквин қылур [Насыйри, 1975, б. 41]; олуғ булса айақдан (آیاقداذ) чығыб төшәр [Насыйри, 1975, б. 51] һ.б.

Мәгълүм булганча, К. Насыйри үзенең «Әнмүзәҗ»ендә (1895) чыгыш килешен аерым килеш итеп күрсәтми, әмма аның барлык стильдә язылган текстларында да чыгыш килешендәге исемнәрнең кушымчалары аерымлана. Шул ук «Әнмүзәҗ»дә: Утыз, утыз биш йылдан (یلدان) бирле ике тел фәнләрендән (فنلرندن), үз телемездән (تلمزدن), вә дәхи рус телендән (تلندن) [Насыйри, 1895, б. 3] һ.б. «Фәвакиһелҗөләса»дә (1884)]: йоқламақдан (یوقلامقدان) киңәйәдер, тереклек итүдән (ایتودن) [Насыйри, 1884, б. 18]; اخلاقدان – әхляқдан, کشیدن – кешедән, کتابدان – китабдан, انجیلدذ – Инҗилдән, قرأندان – Қорьәндан [1884,б.21] һ.б.

Г. Фәезханов үзенең грамматикасында (1887) әлеге килешнең бер генә төрле (әлифсез) адәте алуын билгеләп үтә [Фәизхан, 1887, б. 7]. Автор үзенең әсәрләрендә дә чыгыш килешендәге исемнәрне, нигездә, әлифсез кушымча белән куллана, беренче хезмәтләрендә берникадәр чиратлашу күзәтелә. «Тутыйнамә китабы»нда (1887) эзлекле рәвештә әлифсез кушымча килә: جهتدن – җәһәтдән, تلندن – телендән, حكاياتدن – хикәятдән, سندن – сәндән һ.б. Сирәк кенә искәрмәләр дә очрый: غاشيقدان – ғашыйкдан [Фәизхан, 1887, б.19].» Тарих шәҗарә төрек» хезмәтендә (1891) әлифле вариант кабатлана: ايرندان – йирендән [Фәизхан, 1891, б. 3], اوزندان – үзендән [Фәизхан, 1891, б. 6], حاتونيندان – хатуныңдан [Фәизхан, 1891, б. 9], قزدان – қыздан [Фәизхан, 1891, б. 10] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның кыйссаларында чыгыш килешендәге исемнәрнең әлифле һәм әлифсез кушымчалары белән бергә, тагын *-дин* формасы да шактый актив файдаланыла. «Кыйсса-и Бүз йегет»тә (1874): көннән (كوننان) көнгә, мәндин (مندين) сөенче сораб [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 3]; бер-берендин (بر برندين) аерылмас мәхәббәт дуст иделәр [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 3]; дөнйа бездин үтмәйме [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 5]; қыз йегетдин [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 11]; хан затындан, көнчыгышдан килебди, ата-анадан, андан [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 11]; таудин, ташдин үтебмән [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 13] һ.б.

«Кыйсса-и Таһир илә Зөһрә»дә (1879): уғлы қыздан (قزدان), سببدان – сәбәбдән, طبيبلردان – табиблардан, شهردن – шәһәрдән [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 2]; андин (آنددين) китеб, төрле нәрсәләрдән (نرسه لردن) [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 3]; ғыйшқы көндән (كوندان) көнә, Таһирның ағызындан (اغزندان), гүзәллек бостаныңдан (بوستانندان), қулыңдан (قولندان) китде, аwызындин (آوزندين) бүсәләр алды, ادبسزلكنكدين – әдәбсезлегеңдин [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 6]; йегетләр тарафындин (طرفندين) [Уразаев-Кормаши, 1879, б. 7] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, бу авторда бер үк сүзләрдә чыгыш килеше кушымчалары төрлечә языла.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә (1886) чыгыш килеше кушымчасы, нигездә, бер төрле – әлифсез вариантта кулланыла: Идел нәһерендән (نهروندن), ғади ханәләр кеби ағачдан (آعجدن), صالامدن – саламдан, اورته جامعدن – урта җамиғдан [Акъегет, 1886, б. 2]; تاشدن – ташдан [Акъегет, 1886, 12], انكليزدن – инглиздән [Акъегет, 1886, б. 22], كشدن – кешедән [Акъегет, 1886, б. 23], جختدن – җәһәтдән [Акъегет, 1886, б. 23], تزلكدن – тизлекдән [Акъегет, 1886, б. 26], ارونلروندن – иренләрендән [Акъегет, 1886, б. 40] һ.б.

Р. Фәхретдиннең әсәрләрендә чыгыш килеше кушымчасы шушы ук тәртиптә, ягъни бер вариантта язылá. «Тәрбияле ана»да (1898): бу кешеләрдән (كشيلردن) қайсы усал, ул өй олуғ байлардан (بايلردن) саналынадыр; салқын вә эссе هوادن hawадан сақламақ өчен, андан (آندن) соң дару идәрләр [Фәхретдин, 1898, б. 6], бер хәлдән (حلادن) икенче хәлгә [Фәхретдин, 1898, б. 6]; бу нәрсәләрдән (نرسه‌لردن) дәгел, бәлки туғры аналарының үзләрендән (اوزلرندن) қурқырлар [Фәхретдин, 1898, б. 7] һ.б.

«Тәрбияле бала»да (1898): алтундан (آلتوندن) бәһале, ожмах ниғмәтләрендән (نعمتلرندن) қадерле улған нәрсә, һәр баланың қулындан (قولندن) иртә йокысындан (يقوسندن) [Фәхретдин, 1898, б. 3] һ.б. «Тәрбияле хатын»да (1899): инсанларны ғақыл илә башқалардан (باشقه‌لردن) айырым итмешдер; Алла Тәгалә хәзрәтендән (حضرتندن) һәдийә иделгән никях ниғмәтене [б. 3], ишекдән (ايشكدن) эчкәре керүләренә [Фәхретдин, 1899, б. 5] һ.б.

«Нәсыйхәт»тә (1911): сөтдән (سوتدن) башқа ризық [Фәхретдин, 1911, б. 8], аналары тарафындан (طرفيندن); анлар сездән (سزدن) wәқәр үгрәнсүнләр [Фәхретдин, 1911, б. 9] һ.б.

«Сәлимә, яки Гыйффәт»тә (1899): бу тарихдан (تاريخدن), татар ханларындан (خانلرندن), йөз بڭدن беңдән [Фәхретдин, 1899, б. 3], آنامدن – анамдан [Фәхретдин, 1899, б. 4], قزاندن – Қазандан [Фәхретдин, 1899, б. 7], ساماردن – Самардан [б. 7], ييده‌شلرمدن – ибдәшләремдән [Фәхретдин, 1899, б. 9], бере ислам ғыйлемләрендән (علملرندن), вә икенчесе әхwәли дөнйадан (دنيادن) мәғлүматсыз [Фәхретдин, 1899, б. 10] һ.б. «Әсма, яки Гамәл вә җәза»да (1903): бер данә قزدن қыздан, һәр шәй қулындан (قولندن), мәдрәсәдән (مدرسه‌دن) чығыб, اوستوندن – өстендән [Фәхретдин, 1903, б. 5] һ.б.

Балалар өчен язылган махсус әдәби текстларда чыгыш килеше кушымчасы үзенең барлык вариантлары белән дә кулланыла. Мәсәлән, Т. Яхин төзегән «Сабый вә сабыялар өчен...» җыентыгында (1902) бу хәл ачык күренә: үзенең өйдәш бақасындан (باقه‌سندان) сораған, آچودان – ачудан, йоқысындан (يوقوسندان) күзен ачар-ачмас [Яхин, 1902, б. 5], اوماندين – урмандин бер тарафдин (طرفدين) [Яхин, 1902, б. 10], اوسطادان – остадан, آنباردان – анбардан كوزگيدن – көзгедән, اورندين – урындин, җөмләдән (جمله‌دن) берсе [Яхин, 1902, б. 15] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, әлеге әдиптә нечкә сүзләргә әлифсез язылышлы чыгыш килеше кушымчасы ялгана, ә инде калын сүзләрдә әлифле аффикс белән *-дин* формасы чиратлашып бирелә.

1910 еллардан соң басылган җыентыкларда инде әлифсез вариант кына кулланыла. С. Рахманколыйның «Мөнтазам кыйраәт китабы»нда (1912): كوڭلندن – күңлендән, وقتدن – wақытдан, ياندن – йандан, آچلقدن – ачлықдан, يورهگندن – йөрәгендән [Рахманколый, 1912, б. 2–3] һ.б.

Мәгълүм булганча, мәгърифәтчеләр һәм классик әдипләрнең әсәрләрендә дә чыгыш килешенең, нигездә, әлифсез варианты кулланылышта була. Г. Исхакыйның «Бай угылы» (1910) әсәрендә: дүшәнбе көндән (كوندن), қарчықлар қулларындан (قوللرندن) килгән хезмәтләрене [Исхакый, 1910, б. 163], йулның чатындан (جاتندن) [Исхакый, 1910, б. 164]; озын аwырудан (آورودن), башдан (باشدن) айақ [Исхакый, 1910, б. 164], алты аwыздан (آوزدن) [Исхакый, 1910, б. 165] һ.б. «Тормышмы бу?» әсәрендә: قلاقلر دن – қолақлардан [Исхакый, 1911, б. 16], بولدقسزلغمدن – булдықсызлығымдан, қызның көлүләрендән (كولولرندن) [Исхакый, 1911, б. 17] һ.б.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәлрәсәдән куылуы» (1907) хикәясендә:جهالتدن – җәһаләтдән, بوندن – бундан, татар ағызындан (آغزندن), مدرسهدن – мәдрәсәдән, آناسندن – анасындан [Ибраһимов, 1907, б. 11–12] һ.б.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: йефәк көлтәсе шикелле чәчләрдән (چه چلر دن), بولغانلقلريندن – булғанлықларындан [Әмирхан, 1909, б. 5]; сөйләшүчеләрнең таwышларындан (طاوشلارندن) [Әмирхан, 1909, б. 12]; төрмәдән (تورمه دن) җибәрелгән кеби, ишек төбенә җыелғанлықдан (جييلغالقدن), بغدايدان – боғдайдан [Әмирхан, 1909, б. 14]. «Танымаганлыкдан таныштык» (1909) хикәясендә: طانيماغانلقدن – танымағанлыкдан, ته ره زه لرندن – тәрәзәләрендән [Әмирхан, 1909, б. 5] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, чыгыш килеше кушымчасының язылышында графо-орфографик вариантлылык күзәтелә, әлифсез вариант белән язылыш норма буларак ныгый.

Урын-вакыт килешендәге исемнәр хәзерге татар әдәби телендә *-да/-дә, -та/-тә*, тартымлы исемнәрдә *-нда/-ндә* кушымчасы белән кулланыла, исемне фигыльгә һәм башка сүз төркеменә ияртә [Татар грамматикасы, 2002, б. 55; Хисамова, 2006, б. 90]. Өйрәнелә торган чорда язылган әсәрләрдә урын-вакыт килеше график-орфографик яссылыкта да, функциональ-стилистик яктан да вариантлылык хасил итми. Шуңа күрә бу урында өйрәнелә торган чорда иҗат ителгән әсәрләрдә килешләрнең хәзерге әдәби телдә күзәтелми торган үзенчәле-

генә, ягъни бер килешнең икенче килеш функциясендә файдаланыла алуына игътибар ителә. Әлеге үзенчәлекнең, бигрәк тә, юнәлеш, чыгыш һәм урын-вакыт килешләрендә чагылыш табуы күзәтелә. Югарыда, Г. Кандалыйның «Әбйате чәй бәянында» дигән шигырендә: Ки җәй фасылында бер ирне, һаwа сукса хәрарәтдән, Эчәр булса бу чәйдин ул, Қотылыр ул мәзъәрәтдән... дигән юлларда [Кандалый, 1988, б. 84], тел кануны буенча, *эчәр булса бу чәйне ул* дигән урында төшем килешендәге исем соралуына карамастан, ритм таләбе белән *чәйдин* дип кулланылуы билгеләнде. Сәнгатьле чәчмә әсәрләрдә ритмны саклау-сакламау мөһимлеге күренми, язма норма сөйләмә телгә хас булган иркенлек белән очраша. Бүгенге татар телендә, стилистик максатлардан чыгып, бер килеш урынына икенче килешнең кулланыла алуы мәгълүм [Курбатов, 1978, б. 103–105]. Гасыр башында язылган текстларда да бер килеш мәгънәсенең икенче килеш формасы белән бирелә алуын күзәтергә мөмкин, әмма бу чорда стилистик максат нигез булып тора, дип әйтеп булмый. К. Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы»нда юнәлеш килешенең урын-вакыт, чыгыш килешләре урынына – юнәлеш, төшем килеше урынына – чыгыш һәм иялек, юнәлеш килеше урынына – чыгыш, урын-вакыт урынына – төшем, юнәлеш килеше урынына төшем килешләренең кулланылу очраклары теркәлде: патшаға, аны күргәч, йөз мең шатлык хасил булыр иде [Насыйри, 1974, б. 222], ғыйшық утына сабыры қалмайынча [Насыйри, 1974, б. 222], аwызының қанындан киеменең дүрт йағына ағызып [Насыйри, 1974, б. 222], алардан узып китте [Насыйри, 1974, б. 238]; бармағын аwызына тотып [Насыйри, 1975, б. 169], син һәрқайчан вәзирләреңнең тотып малларын аласың [Насыйри, 1974, б. 242]; минем сездән берсөалем бардыр [Насыйри, 1974, б. 218], падишаһының қызы бер кичне үзенең хилфәт хөҗрәсеннән ғаиб булып [Насыйри, 1975, б. 220] һ.б.

Игътибар белән укыганда, мондый җөмләләрне башка мәгърифәтчеләрнең әсәрләреннән дә китерергә мөмкин. Мәсәлән, М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: зийафәтдә улынанларың бәғзеләре чәйләрене онытыб Бикбулат менланың шәкердләрендән хәйрана қалдылар [Акъегет, 1886, б. 16]; Ғаббас аға вә Шәмси абыстай бөек вә бай адәмләр арасына кереб әқрибалык вә ыруғлық кәсеб идәҗәкләрендән мәсрур иделәр [Акъегет, 1886, б. 36]. Әлеге җөмләләрдәге *шәкердләрендән* сүзе һәм *кәсеб идәҗәкләрендән* сүзтезмәсе үзләре бәйләнгән фигыль белән хәзерге язма әдәби нормада юнәлеш килешендә булыр иде. Классик әдипләрнең башлангыч чор

иҗатларында, бер килеш мәгънәсе еш кына икенче килеш формасы белән белдерелә. Мәсәлән, Г. Исхакый әсәрләрендә хәзерге әдәби норма буенча юнәлеш килеше көтелә торган урында чыгыш килешенең файдаланылуын күрәбез. «Тәгәллемдә сәгадәт»тә: ...башындан салқын су салған төсле, ишек ачып чығып китәр [Исхакый, 1998, б. 47]. «Остазбикә»дә: Қапқа дөбердәгән кебек булғач, Сәғидә остазбикә үзенең сабақ қызларындан бик тиз фонарь күтәртеб йортқа чықды [Исхакый, 1915, б. 26].

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә (1907) урын-вакыт һәм чыгыш килешләре урынына – төшем, төшем килеше урынында – урын-вакыт һәм иялек, урын-вакыт килеше урынына юнәлеш килеше кулланылу очраклары теркәлде: Мин клубның төрле бүлмәләрен йөрергә керештем [Әмирхан, 1984, б. 8]; Өстәлнең бер читендә тора торған зур мөҗәлләд китапларны тотынғанымда,... [Әмирхан, 1984, б. 10]; Мин дә балконның икенче яғына чығып, қояшқа қызынып йөри башладым [Әмирхан, 1984, б. 60]; ...креслоның түренәрәк батып, сүзендә дәвам итте [Әмирхан, 1984, б. 75]; ...сез ничек диннең кешенең вөҗданы белән эше йуқ дисез? [Әмирхан, 1984, б. 81] һ.б. Әмма бу төр җөмләләрдәге сүзләр бәйләнеше хәзерге нормага китерелмәгән очракта да фикер бөтенләй аңлашылмый дип әйтеп булмый, җанлы сөйләмгә хас булган иркенлек булып кабул ителә.

Җанлы сөйләмгә хас булган иркенлекнең эзлекле рәвештә кулланылу очрагы аны билгеле бер чордагы язма норма дип санарга мөмкинлек бирә. Бу үзенчәлекнең хәзерге әдәби телдә, чыгыш килешен таләп итә торган *башка* бәйлеге өйрәнелә торган чорда, юнәлеш килешендәге сүз белән бергә кулланылуы күзәтелә.

Г. Фәезхановның «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» хезмәтендә (1887): Бу ике ғилем бер-берсенә башқа булғанлықдан, һәр қайсын үзалдына берәр китаб итеб, ... басдырырға шөруғ кылдым [Фәизхан, 1887, б. 3]. З. Бигиев әсәрләрендә: Бу мәҗлесдә мәүҗүд улан әшхас һәр қайсы, Ғабденнәсыр әфәндейә башқа, господин Андреевнең бу мәслихәтенә бик шадланып разый улдылар [Бигиев, 1991, б. 232].

*Башка* бәйлегенең юнәлеш килешендәге исем белән кулланылу очрагы Г. Исхакый иҗатында тагын да активлаша: ...дөнйада Ғалиягә башқа бер хатын да йуқ шикелле, һәрвакыт Галийәнең күңелен булдырырға теләр [Исхакый, 1998, б. 49]; ...шәһадәтнамәгә башқа, имтихан бүлегенә бер Қоръән ғазыйм берлән бер сәғәт бирерләр [Исхакый, 1998, б. 43]; ...үзенә алған никъдәр ақчаға башқа, Қәмәрне фатирдан,

кибетдән йолып алырлык ақча да алып,... [Исхакый, 1998, б. 68]; ...бу сырхаwы элгәрге сырхаwына башқа булмаса да... [Исхакый, 1998, б. 74]; ...ялтыраған күккә башқа бер нәрсә күрмим, ... чолғап алған буранға башқа бер нәрсәне дә күрә алмадым [Исхакый, 1902, б. 10]; ...мөселман хатынлары һәм дә марҗалар арасында қалфағына башқа киеме аурупача киенгән бер қыз бар иде [Исхакый, 1998, б. 82]; ...киләчәктәге станциягә төшәргә хәзерләнә торған кешеләргә башқалар һәммәсе йоқлыйлар иде [Исхакый, 1998, б. 85]; ...Бәдрийәгә башқа әллә ничә сөйгән фәхишәләре булғанға,... [Исхакый, 1998, б. 144].

Авторның әсәрләрендә *башка* бәйлеге чыгыш килешендәге исем белән дә кулланыла: Бондый кешеләр Печән базарындан башқа йирдә сүз дә сөйли алмыйлар [Исхакый, 1998, б. 130]; Кәримдән изгелек көткәндә, әүwәл көндүк төн уртасына қәдәр ашаб-эчеб йөреб, исереб қайтудан башқа файда күрсәтмәде [Исхакый, 1998, б. 139]; Бирсәк дә, үземезгә андан зарардан башқа нәрсә булмайачақдыр [Исхакый, 1998, б. 156]. Ләкин әлеге бәйлекнең юнәлеш килешендәге исемнәр белән кулланылуы ешрак кабатлана. Бу үзенчәлек әдипнең тулаем иҗатында урын ала.

*Башка* бәйлегенең юнәлеш килешендәге исем белән кулланылуы Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясендә дә күзәтелә: ...анда кечкенә балыққа башқа бернәрсә дә қапмый [Ибраһимов, 1974, б. 54]; ...аңа башқа тағын берничә кеше бар иде [Ибраһимов, 1974, б. 64].

Авторның «Хәкарәт саналган мәхәббәт» хикәясендә *башка* бәйлеге нуль формадагы, чыгыш һәм юнәлеш килешендәге исем яисә исемләшкән сүзләр белән кулланыла: ...бүген аның қаршында wақыйға кичәгеңәр башқа буйауда күреләә,... [Ибраһимов, 1974, 28]; Шуннан башқа нәрсәне мин кирәксенми дә идем бит [Ибраһимов, 1974, б. 29]; ...үзеннән башқа бер хискә дә урын қалдырмый иде [Ибраһимов, 1974, б. 32]; ...шатлықны үзләренә күрсәтергә өйрәнгән күзләр генә әүвәлгегә башға иделәр,... [Ибраһимов, 1974, б. 32] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, гасыр башында, әдипләрнең барысында да диярлек, *башка* бәйлегенең юнәлеш килеш кушымчасы белән кулланылуы билгеле бер тотрыклы үзенчәлек хасил итә. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында язылган текстларда бер килешнең икенче килеш урынында кулланылу очрагына бик күп санда үрнәкләр китерергә мөмкин һәм, моңа нигезләнеп, хәзерге татар әдәби телендәге традицион алты килешнең форма һәм мәгънәләренең ничек итеп

калыплашуын, ныгуын җентекләбрәк күз алдына китерергә мөмкин. Шуңа күрә алга таба, әлеге мәсьәләгә аерым тукталып, махсус тикшеренүләр уздыру сорала.

Өйрәнелә торган чорда язылган текстларда билгеле бер традицион килеш вазифасының исем янәшәсендә килә торган бәйлек белән дә башкарылуын һәм аларның чиратлаштырылып кулланыла алуын күзәтергә мөмкин. «Кырык вәзир кыйссасы»нда: ...артымдан берәүне җибәр, уғры шәкелендә булып килсен дә кичә белән мине басып алсын [Насыйри, 1975, б. 224]; ...хатындан бу сүзне ишеткәч, ачуы қабарып, ул кичә күзенә йоқы кермәде [Насыйри, 1975, б. 225]; ...кичәдә зифа қыз қулына кергән [Насыйри, 1975, б. 230]. Күренгәнчә, *кичә белән* һәм *кичә, кичәдә* формалары бер үк мәгънәдә чиратлаша.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: ...хәзрәте Сөләйманның ғаскәре эчендән бер сам сувар чығып мәйданға керде. Бер сам сувар дәхи Фисагурис ғаскәрендән чығып мәйданға керде. Сөләйман ғаскәре тарафындан ниндәен сам сувар чыкса, Фисагурис ғаскәрендән дәхи шуның кебек бер сам сувар чығар иде [Насыйри, 1974, б. 210]. Әлеге җөмләләрдә *ғаскәре эчендән, ғаскәре тарафындан, ғаскәрендән* формалары чиратлаша.

Алга таба: ...қулларын зәғфранга батырып; ... кергән хөҗрә ишегенә зәғфран белән биш бармак эзе калдырып керде ...; һәммәсенең ишекләрендә зәғфран белән биш бармақ эзе пәйда булды; ... кемнең ишегендә зәғфран белән бармак эзләре күрсәң; ... ин әүвәл сарай ишегендә зәғфранлы биш бармақ эзе күрде [Насыйри, 1974, б. 242]. Әлеге мисалларда *зәғфран белән биш бармақ эзе, зәғфран белән бармақ эзләре, зәғфранлы биш бармақ эзе* формалары чиратлаша, ягъни баш килештәге исем *белән* бәйлеге ярдәмендә өч мәртәбә кабатлангач, шул ук мәгънә *-лы* кушымчалы сыйфат формасында кабатлана. К. Насыйри иҗатында *белән* бәйлеге гомумән актив, хәзерге күзлектән чыгып караганда, төрле килеш кушымчалары көтелгән урында әлеге бәйлек файдаланыла.

Кайбер килеш формаларының *белән* бәйлеге ярдәмендә чиратлаштырылып кулланылуы Г. Исхакыйның хикәяләрендә дә күзәтелә. «Кияү» хикәясендә: ...мулла-мөәззин белән кода булышкач [Исхакый, 1991, б. 231]; ...мулла мөәззин белән қатышқач, аңар кәшимер күлмәк кирәк инде [Исхакый, 1991, б. 231]; муллаларға қатышқач, мулла әбисе булғач, ... мулла-мөәззин белән қатышқач, мужик төсле затсыз булырға ярамый, ... алар шул мулла-мөәззин белән қатышып ғомер үткәрмәгән... [Исхакый, 1991, б. 231] һ.б. Әлеге мисаллардан аңлашыл-

ганча, абсолют бер үк сүзләр үзара *белән* бәйлеге белән килгән билгесез килештәге исем һәм, шул ук вакытта, юнәлеш килеше кушымчасы ярдәмендә дә бәйләнә ала, әдип аларны чиратлаштырып куллана, бәйлекле вариант ешрак кабатлана.

К. Насыйри әсәрләреннән алынган мисаллар белән дә чагыштырып караганда, болай дип әйтергә мөмкин: *белән* бәйлеге белән килгән баш килештәге исем, билгеле бер контекстта, юнәлеш, чыгыш һәм урын-вакыт килешләрендәге исемнәр белән вариантлылык барлыкка китерә ала, ягъни билгеле бер дәрәҗәдә аларның вазифасын да үти ала.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында язылган текстларда *-дагы* кушымчалы исемнәр дә эзлекле кулланыла. «Кырык вәзир кыйссасы» нда: ...күңлендәге кайгысын вә хафачалыгын [Насыйри, 1975, б. 223]; хәзрәте Сөләйманның йанындағы хәкимнәр [Насыйри, 1974, б. 211]; урмандағы шүрәле кебек булған иде [Насыйри, 1974, б. 227]; бу йаулықны қыз қулындагы қарчыға өстенә сал [Насыйри, 1974, б. 245]; ишекнең тышындағылар күрделәр [Насыйри, 1974, б. 258] һ.б.

Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, бу кыйсса текстында урын-вакыт килешендәге исемгә *-гы* кушымчасы кушылып, нисби сыйфатлар ясалуы күренә. Шуның белән бергә, урын-вакыт һәм юнәлеш килешендәге исемнәр белән вариантлылык хасил итеп кулланылу да күзәтелә.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә әлеге үзенчәлек дәвам итеlә: урамы озайыб, қыйбла тарафындағы очында борылыб, суға йул чыкарыр [Акъегет, 1886, б. 2]; ...өстендәге йоннықы күк камзулы, ... айағында тамбурлы читек-башмақ... [Акъегет, 1886, б. 9]; Арт ханә исә алдағы биек ханә илә тоташ иде [Акъегет, 1886, б. 10]; Һай бу йортдағы тәсадеф [Акъегет, 1886, б. 11]; Мохтарның өстендә қырық йамаулы сары зипун, ... Хисаметдин менланың өстендә йахшы сукно бишмәт, айағындағы читекләре яхшы килешерләр иде [Акъегет, 1886, б. 29] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, *-дагы* һәм *-да* кушымчалы исемнәр үзара алмаштырыла.

Шуның белән бергә, урын-вакыт килешендәге исемгә *-гы* кушымчасы кушылып нисби сыйфатларның [Хангилдин, 1954, б. 103] ясалуы күзәтелә: ...алдағы биек ханә [Акъегет, 1886, б. 10]; ...шәһәрдәге парикмахерның һөнәре иде [Акъегет, 1886, б. 27]; ...бакчадағы кечек бер бинайа [Акъегет, 1886, б. 38] һ.б. З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә: ...фабрикасындағы хезмәтләрен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 93] һ.б. Ф. Кәриминең «Салих бабайның

өйләнүе» хикәятендә: ...урманның буендағы юлдан [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224]; ...күпер өстендәге кызлар [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 226]; күпер өстендә туй ясаган булыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 227] һ.б. Башка әдипләрнең әсәрләрендә дә бу төрдәге сыйфатларның файдаланылуы күзәтелә, алар сыйфат бүлегендә күрсәтеләчәк.

Бу урында урын-вакыт килешендәге исемнәрнең, сыйфат ясагыч кушымча алып, нисби сыйфат вазифасын үти алулары, кайбер мәгърифәтчеләр иҗатында үзенчәлекле кулланылышта булулары турында әйтергә кирәк. Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1898) әсәрендә урын төшенчәсен белдерә торган урын-вакыт кушымчалы исем эзлекле рәвештә *улган* ярдәмлеге белән бергә кулланыла: Қазан шәһәрендә улған ислам мәдрәсәләренең берендә... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 266]; Қазанда улған мәдрәсәдә ун сәнә ғомер уздырып... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268]; Қазанда улған белешләрем... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 269]; ...конторда улған халықлар [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 272]; ...араларында улған мөшабәһәт [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 273] һ.б. Биредә урын-вакыт кушымчалы исем *улган* ярдәмлегеннән башка бик сирәк файдаланыла: Қазан мәдрәсәсендә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 296]; Бакуда мөсафирханәгә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 306] һ.б.

«Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) әсәрендә дә авторның бу үзенчәлеге дәвам ителә – урын төшенчәсен белдерә торган кушымчалы исем *улган, улан* ярдәмче фигыле белән бергә кулланыла: ...кәнде әтрафында улан байларның [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 315]; аwыл қаршысында улан тау башыннан [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 317]; бу мәҗлестә улан кемсә, ...урынында улан тупрақны [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 319]; ...карйәләрендә улан мәсҗет җамиғы [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 321] һ.б.

Классик әдипләрнең беренче әсәрләрендә урын-вакыт килешендәге исемнең *улган, булган* ярдәмлеге белән файдаланылуы күзәтелми. Мәсәлән, Г. Исхакыйның «Капитан кызы» тәрҗемә әсәрендә урын-вакыт килешендәге исемнәр ярдәмлектән башка гына кулланыла: Сембер уездында бер авылында тора башлаған [Исхакый, 1902, б. 4]; ...күз җитмәслек сахрада қар, суқыр итәрлек йақтылық берлән өемләнеп сузылыб җатқан иде [Исхакый, 1902, б. 10] һ.б.

Ф. Әмирханның беренче хикәяләрендә, К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»ндагы кебек үк, *-дагы* кушымчасының еш кабатла-

нуы күренә: «Гарәфә кич төшемдә» (1907) текстында: ...рояль йанындағы қыз белән нәрсәдер сөйләште [Әмирхан, 1984, б. 12]; ...татар дини мәдрәсәләрендәге мөдәрриснең дәрес бирүе [Әмирхан, 1984, б. 13]; ...күзендәге йәшләрен сөртә-сөртә, ...бөтен залдағы бу парларның йегетләре [Әмирхан, 1984, б. 14]; ...алардағы қунақлар [Әмирхан, 1984, б. 16]; ...йанымдағы мендәргә [Әмирхан, 1984, б. 17] һ.б. «Бәйрәмнәр»дә: ...тәравих wақытында қызлар күзләргә йөргән wақытларындағы рамазаннарны [Әмирхан, 1984, б. 18]; ...башқа йыллардағы ғаетләрдәге шикелле... [Әмирхан, 1984, б. 19]; теге бүлмәдәге озын чәчле, йалан башлы егетләр, ...андағы кешеләрне [Әмирхан, 1984, б. 22]. «Хәкарәт саналган мәхәббәт»тә: алдындағы китапта күз йөртә башлады [Әмирхан, 1984, б. 31]; фәқәт аның көндәгедән башқарақ булуына... [Әмирхан, 1984, б. 32] һ.б. Бу мисалларда файдаланылган *-дагы* кушымчалы сүзләрнең барысын да диярлек, *-да* һәм *булган* формасы белән бергә әйтергә мөмкинлек аңлашыла. *-гы* кушымчасы исә, урын-вакыт килешендәге исемгә кушылып, нисби сыйфат вазифасын үти башлый.

*Кыскача нәтиҗәләр.* XIX гасыр – XX гасыр башында язылган текстларда, категориаль грамматик мәгънәсе буенча, җөмләдә исемнең башка сүзләр белән бәйләнеш-мөнәсәбәтен белдерә торган килеш категориясе угыз һәм кыпчак төркемнәре теленә хас булган ике әдәби нормага караган формаларында чагылыш таба.

Әлеге әдәби норма дәвам иткән хәлдә, түбәндәге вариантлылыклар белән кулланылуы күзәтелә: 1) графо-орфографиягә нигезләнгәне: а) баш килешнең нуль формада булуы; ә) иялек килешендә, кыпчак төрләнешендәге исемнәрнең *-ның* (ننك-), угыз төрләнешендә: *-ың* (نك-) кушымчасы белән күрсәтелүе, бер үк әсәрләрдә кыпчак һәм угыз төрләнешенең чиратлаша алуы; б) юнәлеш килешендә, кыпчак төрләнешендә исемнәрнең *-гә, -кә* (كا-, گه-, كه-), *-га, -ка* (عه-, قه-), угыз төрләнешендә, сузыкка тәмамланса, *-йа, -йә* (يه-), тартыкка тәмамланса, *-а, -ә* (ه-) кушымчаларын алуы; в) төшем килешендә кыпчак төрләнешендә исемнәрнең *-ны, -не* (نى-), угыз төрләнешендә, сузыкка тәмамланса, *-йы, -йе* (يى-), тартыкка тәмамланса, *-ы, -е* (ى-), өченче зат тартымлы исемнәрнең *-н* (ن-) һәм *-ны, -не* (نى-) кушымчаларын алуы, соңгы күрсәткечтә булып, ۑ һәм ۏ рәвешендә языла алуы; г) чыгыш килеше аффиксының әлифле (دان), әлифсез (دن), шулай ук *-дин* (دين-) булып язылышы; е) урын-вакыт килешенең бер генә вариантта (ده-) язылуы;

2) морфология нигезләнгәне: а) традицион алты килешнең һәрберсенең төрле мәгънә мөнәсәбәтләрендә, үзенең төп вазифасын

башкаруы; ә) традицион алты килеш аффиксларыннан башка тагын: *-дагы, -ныкы, -дай, -лы, -сыз* кушымчаларының да килеш вазифаларын үтәүләре; б) бер килеш кушымчасының икенче килешнең мәгънәсен бирүдә дә файдаланыла алуы;

3) синтаксиска нигезләнгәне: кайбер килешләрнең мәгънәсе һәм вазифасы, ягъни сөйләм барышында башка сүзләр белән бәйләнеше, кушымчалар белән дә, шул ук вакытта бәйлек һәм бәйлек сүзләр белән дә белдерелә алуы һ.б.

Килеш категориясенә хас булган әдәби норма һәм аның норма вариантлары аерым жанр-стильдә язылган текстларда махсус сайланып кулланылганга күрә, алар функциональ-стилистик вариантлылык та хасил итә. Гомумтөрки укучыга багышлап язылган әсәр һәм хезмәтләрдә иялек, юнәлеш һәм төшем килешләре угыз-көньяк төрләнешендә, татар укучысы өчен дип язылган әдәби әсәрләрдә кыпчак-төньяк төрләнеш күрсәткечләре белән кулланыла. Классик язучылар иҗатында әлеге мөмкинлекләр образ барлыкка китерү чарасы буларак та файдаланыла, әмма биредә татар теленең үз формалары активлаша.

## 5.2. Сыйфат

Төрле лексик-семантик һәм асыл-нисби дигән төркемчәләргә бүлеп карарга мөмкин сүзләрнең, предметның киң мәгънәсендә процессуаль булмаган статик билгесен белдерә торган гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә лексик-грамматик яктан берләшеп, башка сүз төркемнәреннән аера торган формаль күрсәткече булмаганга, морфологик яктан формалашмаган, синтаксик планда, исемгә янәшәлек юлы белән бәйләнеп, процессның билгесен белдерү позициясендә хәл функциясен үти алучы, шулай ук хәбәр булып кулланыла, исемләшкәндә, исемгә хас булган үзенчәлекләрне алырга мөмкинлеге булган *сыйфат* сүз төркеменә караган сүз, сүзформа, сүзтезмәләр [Татар грамматикасы, 2002, б. 65–71] XIX гасыр – XX йөз башында төрле жанр-стильдә язылган текстларда да кулланылышта була.

Гомумтюркологик хезмәтләрдә предмет, күренешләрнең статик халәттәге билгесен белдерә торган сыйфатларның күпчелегенең, рәвеш кебек үк, процессның да билгесен белдерә алуына игътибар ителә. Галимнәр белдергәнчә, хәзерге вакытта бер генә төрки телдә дә әлеге мәсьәләне, ягъни кайсы сыйфатларның предметның гына, ә кайсыларының һәм предмет, һәм процессның да билгесен белдерү үзенчәлеге, теоретик яктан нигезләнеп, гамәли яктан барланып тикшерел-

мәгән. Тарихи планда нисби сыйфатларны аерып алырлык морфологик күрсәткечләрнең формалашмаулары сәбәабле, асыл һәм нисби дип бүленә торган сыйфатларның берсен икенчесеннән аерып карау төрки телләрдә җиңел булмавы искәртелә. Нисбилек мөнәсәбәтенең берсе атрибутив функциясендә булган ике исем (изафә), исем һәм асыл сыйфатларны ясый торган *-лы, -лык, -сыз, -кы, -гы, -чы* һ.б. кушымчалар белән күрсәтелүе ассызыклана [СИГТЯ, 1988, с. 148–154]. «Языки мира: Тюркские языки» дигән энциклопедик хезмәттә урын алган аерым мәкаләләрдә сыйфат сүз төркеменең бу үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирелә [Языки мира, 1997, с. 365]. Кайбер авторлар сыйфат һәм рәвешләрне аермыйча бергә карый, аларның категориаль мәгънәсен исем яисә фигыль белән кулланылуына карап кына билгеләргә мөмкин, дип саный [Языки мира, 1997, с. 96] һ.б.

Л. Җәләйнең монографиясендә сыйфат сүз төркеме, асылда, тарихи планда өйрәнелә. Сыйфатның семантик һәм грамматик үзенчәлекләре дигәндә, түбәндәге мәсьәләләргә игътибар ителә: «...сыйфатларны башка сүз төркемнәреннән аерып торган бер үзенчәлек – логик төшенчәдән тыш метафорик төшенчәгә ия булу: *суык бәгырь, каты күңел, татлы җан*; асыл һәм нисби сыйфатларга хас төсмерләрне анык исәпкә алып, тулы һәм төгәл бүлү бик үк ансат эш түгел» [Җәләй, 2000, б. 57]. Шуның белән бергә «Асыл сыйфатлар төп һәм ясалма (ямьле, тәмле, эшчән, уйчан), нисби сыйфатлар (быелгы ел, кышкы юл, авылдагы апам) ясалма формада гына булалар... Татар телендә асыл һәм нисби сыйфатлар арасындагы уртак грамматик форма итеп, аларның һәр икесе дә җөмләдә аергыч булып (төп функция) үзләре караган сүзнең – аерылмышының алдында (препозитив) килергә тиешлек карала ала», – дип белдерелә [Җәләй, 2000, б. 59]. Сыйфат сүз төркеменең өйрәнелү тарихын җентекләп өйрәнү барышында, автор: «...В.Н. Хангилдин “Татар теле грамматикасы”ның һәр ике басмасында сыйфат сүз төркеменә иң тулы характеристика бирә», – дип яза [б. 64].

Хәзерге татар теле грамматикасында сыйфат сүз төркеме [Татар грамматикасы, 2002, б. 65–70], В.Н. Хангилдин хезмәтенә нигезләнеп бирелә, аның кыскартылган варианты булып тора [Хангилдин, 1954, б. 82–115].

Иске татар телендә язылган истәлекләрне тикшерүчеләрнең хезмәтләреннән аңлашылганча, бу сүз төркеменә күпчелек авторларның игътибар итүе, әмма төрле авторда төрле дәрәҗәдә анализлануы күренә [Ахметгалеева, 1979, с. 85; Хисамова, 1999, с. 191, 205, 225,

349–350; Нуриева, 1999, с. 78–81; Гилемшин, 2001, с. 95–97; Исхакова, 2005, с. 98–115; Юсупов, 2006, с. 49–63; Мирхаев, 2007, с. 51–56; Абдулхаков, 2010, с. 129–132; Гайнуллина, 2010, с. 47–53, Миңнуллин, 2012, с. 133–138 һ.б.]

XIX гасыр – XX гасыр башында иҗат ителгән әсәрләрдә сыйфат сүз төркеменә берләшә торган сүзләрне тикшергәндә, В.Н. Хангилдин хезмәте белән бергә, аларның язма истәлекләрдә кулланылышы анализланган хезмәтләргә игътибар ителә, хәзерге әдәби телдә өйрәнелә торган тәртип саклана [Татар грамматикасы, 2002, б. 65–71; Хисамова, 2006, б. 282–291]. Тезмә һәм чәчмә әсәрләр аерым тикшерелә.

XIX гасырның беренче һәм икенче яртысында төрки-татар теленең классик абруйлы төрендә иҗат ителгән поэзия әсәрләрендә, төрки-татар теленең үз сыйфатлары белән бергә, гарәп-фарсы теленең сыйфатлары һәм предметның билгесен белдерә торган сыйфат фигыльләрнең эзлекле кулланылуы күзәтелә.

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» (1845, 1889) әсәрендә файдаланыла торган сыйфатларны берничә лексик-семантик төркемгә бүлеп карарга мөмкин.

1. Шәхеснең характерын, психик, акыл үзенчәлеген белдерә торган сыйфатлар. Бу әсәрдә боларның күбесенең сыйфатлау тәркибе һәм фарсы изафәсе ярдәмендә бәйләнеп бирелүләре күренә [Мәхмүтов, 1965, б. 847–848]:

а) сыйфатлау тәркибе, ягъни сыйфат һәм сыйфатланмыштан торган сүз тезмәсе: шәйһе җиһан (җиһанның дин башлыгы) [Каргалый, 1889, б. 2]; сахибе кәрамәт (могҗизаның иясе) [Каргалый, 1889, б. 5] һ.б.

ә) изафә тәркибе, исемнең азагына *-и* кушымчасы ялгану белән ясала: кәримә-и ниса (хөрмәтле хатын) [Каргалый, 1889, б. 2]; дөхтәр-и дүшизә (гыйффәтле кыз) [Каргалый, 1889, б. 5]; мәккяр-и пирәзәндер бу (мәкерле карчык ул), ниғмәт-и ғыйзамайа (муллыкның бөегенә) [Каргалый, 1889, б. 7]; шәфкәт-и сахибән валидән (шәфкать иясе анадан) [Каргалый, 1889, б. 8]; пәйгамбәр-и ғалиҗәнаб (бөек пәйгамбәр) [Каргалый, 1889, б. 9] һ.б.

б) сыйфатлы изафә, беренче сүз сыйфаттан, икенче сүз артикльле яисә артикльсез исемнән гыйбарәт булган кушма сыйфатлар: һиммам-әл-мөэминин (мөэминәрнең һиммәтлесе), зинн-ел-риҗал (ирләрнең зиннәте), хәйре-л-бәшәр (адәмнәрнең яхшысы) [Каргалый, 1889, б. 2]; рәхмәт-әл-ғаләмин (галәмнең мәрхәмәтлесе) [Каргалый, 1889, б. 4]; ул зат-ел-мәкярим (ул мактаулы зат) [Каргалый, 1889, б. 5] һ.б.

Раббының, шәхеснең, кешеләрнең бөеклеген белдерүдә, нисби сыйфатлар белән рәттән, гарәп һәм фарсы теленең үз асыл сыйфатлары кулланыла: иманындин ғазиз (иманыннан кадерле) [Каргалый, 1889, б. 3]; дәүри әсхабе (дәвер хуҗалары) [Каргалый, 1889, б. 3]; мөбарәк рухына [Каргалый, 1889, б. 7] һ.б.

Текстларда гарәп теленең сыйфат фигыльләредә файдаланыла: гали нәсәб (төрки-татар текстында асыл сыйфат булып кабул ителә – бөек нәсел-ыруг) [Каргалый, 1889, б. 2]; рәсүле мөхтәрәм (төрки-татар текстында *-лы* кушымчалы ясалма асыл сыйфат буларак кулланыла – хөрмәтле рәсүл [Каргалый, 1889, б. 3] һ.б.

2. Зат һәм предметларның тышкы күренешен, зурлыгын, күплеген белдерә торган сыйфатлар да берничә ысул белән бирелә: а) сыйфатлау тәркибендә. Бу юнәлештә *әһел* (кешеләр) дигән исем белән тезмә ясап файдалана торган сыйфатлар эзлекле кулланыла: әһле гәдә (хәерче кешеләр), әһле залл (азгын кешеләр), әһле хәл (көчле кешеләр), әһле фәкре (фәкыйрь кешеләр) [Каргалый, 1889, б. 3] һ.б.

ә) сыйфатлы изафә: әүләд-и сәғыйрь (кечкенә балалар) [Каргалый, 1889, б. 4]; вәләд-и сәғыйрь (кечкенә бала) [Каргалый, 1889, б. 8] һ.б.

б) гарәп-фарсы алынмалары татар теленең үз сыйфатлары белән чиратлаша, яисә сүз тезмәсе хасил итә: фетнәдер берсе хәддин йаман [Каргалый, 1889, б. 2]; тохмы қарбыз пөр (тулы)бәһә булды, [Каргалый, 1889, б. 3]; Хак өчен вирмәя коругъ наныны (коры икмәкне бирергә) [Каргалый, 1889, б. 3], вирер аңа эстәдегендин зийад (теләгәненнән артык бирер) [Каргалый, 1889, б. 3]; нәчә көнләр бер мөһаҗир ач-у-зар [Каргалый,1889, б. 4]; әйләмәс асла болар сабыр-у-пәзир [Каргалый,1889, б. 4] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, зат һәм предметларның төрле билгесен белдерә торган *сау, сәламәт, сукыр, явыз, яман, бай, каты, нәкәс, изге, нык, артык, чиста, кара* һ.б. асыл сыйфатларның гарәп-фарсы алынмалары белән дә, төрки-татар сүзләре белән дә, *ул, бул, әйләү, ирер, эш, хәл* ярдәмлекләре белән бәйләнештә, тезмә фигыль (процесс) билгеләрен белдереп тә кулланылулары аңлашыла. Алар: «...фигыль төшенчәсендә дә табылуы мөмкин булган билгеләрне белдерә алалар... нәкъ шушы ноктада бу төркемчәдәге сыйфатлар рәвеш белән очрашалар», – дип әйтергә мөмкинлек бирә [Хангилдин, 1954, б. 84], ягъни эш-хәлнең, процессның билгесен белдерү функциясендә дә кулланыла ала.

Бу әсәрдә, күбрәге гарәп-фарсы сүзләре, азрагы татар-фарсы сүзләре белән кушылып ясалган сыйфатлар белән бергә, фарсы теленең барлыкны белдерә торган *ба*, юклыкны белдерә торган *би* бәйлеге һәм шул ук вазифадагы *на* кисәкчәсе белән ясалган сыйфатлар да кулланыла: ...җәwабы басаwаб (җавабы саваблы), ... би иман (имансыз) китмәкнең [Каргалый, 1889, б. 2], ... би тәмиз (пычрак) [Каргалый, 1889, б. 3], улимазуз на өмид (булмабыз өметсез) [Каргалый, 1889, б. 3] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, Ә. Каргалыйның әсәре аристократ-абруйлы төркидә язылганга күрә, башка сүз төркемнәре кебек үк, сыйфат сүз төркемендәге сүзләрнең күбесе гарәп һәм фарсы алынмалары булуы күренә.

Һ. Салиховның «Китабы мәҗмәгыль адәб» хезмәтенең дә шундый ук төркидә язылганлыгы мәгълүм. Бу әсәрдә дә нисби сыйфатлар исемнең аергычы булып килү тәртибендә ясала торган тезмәләр булып кулланыла: Һидайәт вир сыйрат мөстәкыймәт, Йулы сабдырмағыл раһ сәқыймәт (туры-дөрес юл эзләү теләге бир, начар юлларга туры китермә) [Салихов, 1856, б. 3] һ.б.

Төрки-татар текстында сыйфат булып файдаланыла торган гарәп асыллы сыйфат фигыльләр, ярдәмлекләр белән бергә килеп, тезмә хәбәр функциясендә кулланыла: Безә қоллықда кәндүзнең мөгайун ул, Ғобудийәт йулин безә мөбин ул [Салихов, 1856, б. 2]; виреб ғали сәғәдәт әйләгел шад [Салихов, 1856, б. 3] һ.б.

Предметның күләм-чама ягыннан билгесен белдерә торган бер үк сыйфатларның, затка караган вазифасын үтәп тә кулланылулары күренә: олуғ таш [Татар әдәбияты, 1957, б. 54], олуғ йулдин [Татар әдәбияты, 1957, б. 61], олуғ димә, кечек димә [Татар әдәбияты, 1957, б. 62] һ.б.

Ш. Зәки шигырьләрендә кулланылган сыйфатлар, чыганак телләренә карап, төрки-татар, гарәп һәм фарсы дип бүлеп, А.Ф. Йосыпов хезмәтендә җентекләп тикшерелә. Аерым мисалларда (фарсы сүзләре булган *гөнаһ, ляикъ, хәя* сүзләренең төрки-татар дип аңлатылуы, яисә *йырак* рәвешенең сыйфат дип бирелүе кебек) кайбер керешеп китүләр күзәтелүгә карамастан, иске татар телендәге текстта файдаланыла торган сыйфатларның бу рәвешле өйрәнелүе, Ә.Р. Исхакова хезмәте кебек үк [Исхакова, 2005, б. 98–115], алга таба үрнәк булып санала ала [Юсупов, 2006, с. 49–63].

Г. Кандалый шигырь һәм поэмаларында, мәгълүм булганча, «... илаһи гүзәллеккә ия җәннәт чибәрләренең үзләрен җир кызының табигый матурлыгыннан сокландыра, ... мәхәббәтне “мәңгелек категория”

итеп карарга омтыла, ... матур сүзләрне өсте-өстенә өеп, хис “ябырылдыру”да, гашыйкның мәгъшукасына булган ихлас омтылышын җыр югарылыгында гәүдәләндерүдә шагыйрь Сахибҗәмалга мөрәҗәгатендә аерата виртоузлык күрсәтә» [Кандалый, 1988, б. 45–47]. Матур сүзләрнең күбесе, әлбәттә, сыйфат сүз төркеменә каравы аңлашыла.

Сөйгән ярның физик халәтен, килеш-килбәтен, тышкы кыяфәтен һәм акылын сурәтли торган сыйфатлар, ул яши торган тирә-юньнең матур төсләре белән бергә үрелеп тасвирлана: асыл җәй фасылы, йәшел чирәм, гүзәл мәхбүб [Кандалый, 1988, б. 80]; ләтыйф сүзләр [Кандалый, 1988, б. 86]; матур зат [Кандалый, 1988, б. 102]; ҡара ҡашларың [Кандалый, 1988, б. 105]; Әйа җаным, нечкә биллем, Үзең зирәк, үзең ғыйлем [Кандалый, 1988, б. 107]; Ҡызыл гөлдер сәнең йөзең, Ҡызыл йаҡут сәнең ирнең [Кандалый, 1988, б. 107] һ.б.

«Сахибҗәмал» поэмасында: чибәрем лә, и матурым, сөйәрем лә, гүзәл сән алтын алмадай, сәнең дик сылу йарлар да, зифа буй, нечкә билләр дә [Кандалый, 1988, б. 388]; ...гүзәлсән бик Парауда бер, ... матурсән – күз ҡарауда бер, сылу чабың, матур даның [Кандалый, 1988, б. 390]; сылу чабың, матур исмең, җәмалың ҡадрене [Кандалый, 1988, б. 391] һ.б.

Әлеге тасвирларны тәм ягыннан билге белдерүче сыйфатлар көчәйтеп җибәрә: ләзиз ниғмәтләре [Кандалый, 1988, б. 84]; сүзеңдер шикәрдин датлы [б. 107], бал-шикәрдин татлы сәнең сүзләрең бар [б. 109], телең татлы сөчек бал [Кандалый, 1988, б. 132]; ашар ашың сәнең шикәр, сары май [Кандалый, 1988, б. 208]; сүзең ширин [Кандалый, 1988, б. 209] һ.б. Бу юнәлештә татарның үз сүзләре күбрәк кулланыла, *-лы* кушымчалы ясалма сыйфатлар, асылда, бер предметның икенчесендә табылуын уңай бәяләү төсмере белән чагыштырып белдерә.

Физик халәтне белдерә торган төрки-татар теленең сыйфатлары да алынма сүзләр белән чиратлаштырыла: ҡаты ташдай йөрәкләрне [Кандалый, 1988, б. 80]; мөссафа бал, чын кяса [Кандалый, 1988, б. 87]; сбижий бинек, ҡайнар су [Кандалый, 1988, б. 101]; йомшар иде ҡаты ташлар [Кандалый, 1988, б. 110], сөйләшдек ҡаты сер сүзләр [Кандалый, 1988, б. 139] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, асыл сыйфатлар туры мәгънәдә дә, күчерелмә мәгънәдә дә, нигездә, тамыр хәлендә файдаланыла.

Сөйгән ярының күркәм, чибәрлегенең күләм-микъдарының үсеш дәрәҗәсе белдерелә бару уңаендә, автор гарәп вә фарсы алынмаларын

файдалана башлый: озын булса әгәр ғомрем [Кандалый, 1988, б. 79]; бик һәйбәт, сафа мәкянедер [Кандалый, 1988, б. 80]; бөек шадлык [Кандалый, 1988, б. 81]; ләтыйф сүзләрене [Кандалый, 1988, б. 86]; газиз балам [Кандалый, 1988, б. 90–-91, 93]; һ.б

Урыны-урыны белән мәхәббәтнең көче-микъдаре ни дәрәҗәдә булуын сурәтләү өчен, автор рәттән гарәп-фарсы алынмаларына күчә: Ғыйлемлек нурани җәүһәр [Кандалый, 1988, б. 71]; Дәрдлә зар-у-пәришаным мәнем, Әй никярем, гөлғизәрем, сәрви қәдд, Вай ләбе ғөнҗә, даһани лялә хәдд [Кандалый, 1988, б. 119]; Сарыйғ идеб йөземезне чүн лялә-зар, Доға-и хәйремез бу җан-и садыйқ [Кандалый, 1988, б. 121] һ.б. Аннан төрки-татарның үз сүзләре китә: Ходай қылған сәнең йөзеңне күркәм, Ходай қылған зифа буеңны өлкән [Кандалый, 1988, б. 209]; ...бер тамаша: бу ғашыйқлық берлә күңел азмасын, Ағыр икән, хәсрәте чуқ – дошманыңа йазмасын [Кандалый, 1988, б. 211] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, күп кенә сыйфатларның I зат берлек сандагы тартым кушымчасы белән эндәшү функциясендә файдаланылуы аңлашыла.

Һәр яктан килгән гүзәллеккә ия абыстайны белемле-гыйлемле муллага гына яр булырга тиеш дип үгетләгәндә дә, автор, төрки-татар теленең сыйфатлары белән бергә, гарәп-фарсы алынма сыйфатларына да мөрәҗәгать итә: Қарағач бу төсең қалмас, Көсүф алмыштый көрсәттә калганда [Кандалый, 1988, б. 152]; ...мөнәүүәр җәмалың чөн басты қайғу [б. 156], ... гаҗәб ләтыйфәдер җисмең [Кандалый, 1988, б. 157]; Кийәү итсәң надан ирне үзеңә, Қыйәмәттә қара йақар йөзеңә [Кандалый, 1988, б. 162]; ...матур булсаң да, барғачдин наданға. Керәлмассән ғомер буенча санға [Кандалый, 1988, б. 163] һ.б.

Мөләем, чибәр кызны санга сукмый торган надан, укымаган, намаз белмәгән, чиркен чырайлы ирнең характерын, физик халәтен, килеш-килбәтен, акыл ягыннан билгесен белдерә торган сыйфатлар гүзәл кызның матурлыгына каршы куелып сайлана: надан кеше көтү көтәр, ғалим кеше Бохар китәр [Кандалый, 1988, б. 79]; ...сарып башқа қара өрпәк, киеп пәҗи қара күлмәк, қара гарәб кеби бите [Кандалый, 1988, б. 82]; ...чытык йөзләр, түбән қашлар [Кандалый, 1988, б. 98]; ...надан ир, надан бер кара мажикка, барырсың андый фасиққа [Кандалый, 1988, б. 391]; ...надан йарга [Кандалый, 1988, б. 396] һ.б. Аңлашылганча, һәр яктан килгән күркәм-гүзәллекнең юкка чыгу куркынычы да сурәтләнә бара.

Шулай итеп, Г. Кандалый иҗатында, сыйфатның төрле лексик-семантик төркемчәләре үзләренең барлык мөмкинлегендә файдаланыла. Аларның хәзерге әдәби телдәге кебек, лексик-грамматик үзенчәлекләрен күзәтеп була.

Югарыда искә алынганча, асыл сыйфатлар исемләшеп, I зат тартым күрсәткече белән, чибәр абыстайга эндәшү вазифасында эзлекле файдаланыла: чибәрем лә, и матурым, сөйәрем лә, гүзәлем, сылуқаем, қызыл алма [Кандалый, 1988, б. 114]; зар-у-пәришаным, әй никярем, гөлғизарем, [б. 119]; нечкә билем, қызыл алмам, әйа дилбәр [Кандалый, 1988, б. 125] һ.б. Исемләшкән сыйфатлар эндәш сүз булмыйча да кулланыла: ғыйшыққа дару йуқ диләр зирәкләр [Кандалый, 1988, б. 150] һ.б.

Асыл-ясалма сыйфатлар ярдәмендә авторның ялкынлы эмоциональ кичерешләре тасвир ителә: ба тәүфиқ, күрекле йар, инсафлы бала, бинәва, биғөман, мәхәбәтсез кешедән бик йырақ қач [Кандалый, 1988, б. 95]; қадерсез шул қәдәр йортта... [Кандалый, 1988, б. 83]; моңлы зар [Кандалый, 1988, б. 96], сары тулды нурлы йөзгә [Кандалый, 1988, б. 111]; ...күз күрекле йарны сәүмәк [Кандалый, 1988, б. 135] һ.б.

Нисби сыйфатлар «нисбәт яки мөнәсәбәт [отношение] төшенчәсен белдерә, сыйфат дәрәҗәләрен тәгъбир итә алмый, исем белән исем ролендәге сүзләр белән синтаксик мөнәсәбәткә керә» [Хангилдин, 1954, б. 102]. Язма традиция дәвам ителеп, Г. Кандалый иҗатында да, бу төр сыйфатларның күбесе гарәп һәм фарсы теле кагыйдәсе буенча бирелә:

1) ике исемнең беренчесенең азагына *-и* кушымчасы ялгану белән ясала, бер исем икенчесен сыйфатлый, гарәп телендәге сыйфатлау һәм изафә тәркибе рәвешендә кулланыла: доға-и хәйремез, җан-и садыйқ, бәдр-и лямиғ дилбәрә, әфзал-и нисани [Кандалый, 1988, б. 103]; бәхр-и дәрдкә гарқ улыб мән [Кандалый, 1988, б. 135]; интияа-и ғыйшық улмаз [Кандалый, 1988, б. 136]; бостана сәрвийе-назым [Кандалый, 1988, б. 167] һ.б.

2) беренче сүз сыйфаттан, икенче сүз артикльле яисә артикльсез исемнән гыйбарәт булган мөнәсәбәттә кушма сыйфатлар (сыйфатлы изафә) барлыкка килә: нурани җәүһәр, хәйр-ел-мөҗиб, зу-л-кәрәм, нәзәнин-хәйр-ел-бәнат, миһербани дилнәуазем [Кандалый, 1988, б. 167] һ.б.

Гарәп теленең 3нче баб масдары татар сүзенең аергычы буларак кулланыла: мөляқәт көненә тиз дә ирештерсен үзе Алла [Кандалый,

1988, б. 90] һ.б. Гарәп теленең сыйфат фигыле аергыч ролен үти: мөшкил хәл [Кандалый, 1988, б. 92]; мөшкелдер сәнең тормышың [Кандалый, 1988, б. 93] һ.б.

3) *-лы/-ле, -сыз/-сез* кушымчалы нисби сыйфатлар: үкчәсез чабата [Кандалый, 1988, б. 82]; күземдин ағадыр қанлы йәшләр [Кандалый, 1988, б. 110–111, 146]; ақ чырайлы қара қашым [Кандалый, 1988, б. 111] һ.б.;

Татар телендәге сыйфат һәм исем фигыльләрнең предметның билгесен белдереп кулланыла алулары нисби сыйфатлар рәтендә карала:

а) *-ыр/-ер (-ар/-әр)* кушымчалы сыйфат фигыльләр: ағар су тирәсе таллы [Кандалый, 1988, б. 91]; ярамас қызға күз салсам [Кандалый, 1988, б. 75]; йана бәғрем, уты сүнмәс [Кандалый, 1988, б. 92]; қаwышыр көн булырмы [Кандалый, 1988, б. 117]; күрер күзем, сүләр сүзем сән [Кандалый, 1988, б. 131]; қачан булыр қысыб сәүәр көн [Кандалый, 1988, б. 131] һ.б.;

ә) *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльдән күчкән сыйфатлар: туған илем [Кандалый, 1988, б. 75]; шималә қаршы ақған су [Кандалый, 1988, б. 87]; ...түгелгән йимешең [Кандалый, 1988, б. 89]; тулған айға [Кандалый, 1988, б. 109]; сәүгән йарын [Кандалый, 1988, б. 110]; барған йиреңдә, барған ирендә [Кандалый, 1988, б. 161] һ.б;

б) *-ачак/-әчәк* кушымчалы сыйфат фигыльдән күчкән сыйфат: Йөзеңдин нурларың ағыла, Күрәчәк күзләр чағыла [Кандалый, 1988, б. 159] һ.б.;

Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, төрле лексик-семантик һәм лексик-грамматик төремнәргә бүленә торган сыйфатларның, хәзерге татар телендәге кебек, асыл, нисби, тамыр, ясалма рәвешендә файдаланылуы аңлашыла.

Сыйфатның сүз сөрешендә (контекстта) исемләшүе күзәтелә, ягъни сыйфатланмышыннан башка килгән сыйфат исем кебек үк төрләнә башлый: онытмам сез наданнарны [Кандалый, 1988, б. 76]; барыр булсаң наданға, салам салып йабып куйар аранға [Кандалый, 1988, б. 105]; зифалығың ғорурында... [Кандалый, 1988, б. 139]; ...Бәнем илә күрешсәнә ниһанда [Кандалый, 1988, б. 169]; ...Иляһы, ошбу матурға насыйб ит бергә йатырға [Кандалый, 1988, б. 148]; баралсаң бәндин артыққа [Кандалый, 1988, б. 166] һ.б.

Кайбер сыйфатлар, процессның билгесен дә белдереп, хәл функциясендә файдаланыла: ...жаныкаем йахшы аңла, йахшы аңлап торың имди [Кандалый, 1988, б. 113]; озын итсен сезнең ғомрегезне Хақ

[Кандалый, 1988, б. 120]; сәнең буең, җаныкаем, зифа үссә [Кандалый, 1988, б. 113] һ.б.

Сыйфатлар *бул-, кыл-* фигыльләре белән янәшә кулланылганда, тезмә хәбәр вазифасында килә: зирәк булсаң, белерсең бу хәлемне [Кандалый, 1988, б. 130]; ғақыл улсаң, сүзем тот и нигярем [Кандалый, 1988, б. 130]; шад қылғыл, азад қылғыл [Кандалый, 1988, б. 154]; қадерсез қылма [Кандалый, 1988, б. 261] һ.б.

Бу мәсьәләне В.Н.Хангилдин болай дип аңлата: «...предметка хас сыйфатлар, гомумән алганда, эш (действие), хәл билгесен белдермиләр. Хәтта синтаксик яктан янәшәлек юлы белән фигыльгә бәйләнү очракларында да, алар эшнең түгел, бәлки предметның билгесен белдерәләр: игеннәр әле яшькелтрәк күренәләр, бүген көн аяз күренә, бу аш миңа тозсызрак тоелды һ.б... Бу фактлар предмет сыйфатларының фигыльгә бәйләнүе бары тышкы бер факт кына булуын күрсәтәләр... Предметка хас сыйфатлар күчерелмә мәгънәләрдә (метафорик) кулланылганда, чын-чыннан эш-хәл билгесен дә белдерә алалар: *бу хат бик тозсызрак язылган, чебеннәре бик ачы тешли башладылар* җөмләләрендә тозсыз, ачы дигән предмет сыйфатлары, күчерелмә мәгънәләрендә үзләре бәйләнгән фигыльләр белән белдерелгән эш, хәл төшенчәләренең чын-чыннан билгеләрен аңлаталар. Ләкин бу мәгънәләре буенча инде алар, предметка хас сыйфат булудан чыгып, предмет һәм эш-хәл сыйфатына әйләнәләр...» [Хангилдин, 1954, б. 83–84]. Димәк, тикшерү барышында, кайсы сыйфатларның фәкать предмет билгесен генә, ә кайсыларының, предмет билгесе белән бергә, процессның да билгесен белдерә алуларын күз уңында тотып аера барырга тиеш булабыз. Әлеге мәсьәлә галим тарафыннан татар теле белемендә тикшерелмәгән дип белдерелә [Хангилдин, 1954, б. 84–85].

Текстларда башка сүз төркемнәре дә сыйфат (аергыч) урынында кулланылалар.

1 нче төр изафә формасында кулланыла торган ике исемнең беренчесе аергыч функциясен үти: көмеш қашық илән алың [Кандалый, 1988, б. 87]; иман нуры йөзеңезгә [Кандалый, 1988, б. 95]; көмеш йөзек кийәсең, әй, қулыңа, уқа йақа сапқансың, әй, муйыныңа [Кандалый, 1988, б. 115]; төп гөлем булғыл [Кандалый, 1988, б. 116]; қолағында көмеш алка [Кандалый, 1988, б. 128, 138] һ.б.

2 нче төр изафә формасында кулланыла торган ике исемнең беренчесе аергыч вазифасын үти: ғыйшық уты [Кандалый, 1988, б. 114, 116]; мәхәббәт атәшенә, ғыйшық дәрде [Кандалый, 1988, б. 120]; кү-

зем йагын [Кандалый, 1988, б. 125]; ғыйшық утыдин [Кандалый, 1988, б. 131]; мәкәрҗә қалфағы [Кандалый, 1988, б. 138] һ.б.

3 төр изафә формасында кулланыла торган ике исемнең беренчесе аергыч вазифасын үти: сән нигярның хәндәсе [Кандалый, 1988, б. 134]; ғыйшықның пәйаны [Кандалый, 1988, б. 136]; ...гөлнең нуры китә, матур қызның қадере китә йегерме йәшенә йиткәч [Кандалый, 1988, б. 147]; ...дөнйаның зәwқен [Кандалый, 1988, б. 149] һ.б.

Аерым рәвешләр исемнең билгесен (микъдарын) белдерә: йә күп йылга, йә күп айга хисабың бармы сайларға [Кандалый, 1988, б. 212]. һ.б. Рәвеш ясый торган *-дай/-дәй, -тай/-тәй (-дақ/-даг, -дәк/-дәг, -дик-тик)* кушымчасы белән «ясалган сүзләрнең кайберләре (аеруча исемнән ясалганнары) сыйфатка да шактый якын торалар; сүз тезмәсендә исемнәргә бәйләнеп аергыч булалар» [Хангилдин, 1954, б. 290]. Г. Кандалый иҗатында менә шундый тезмәләр еш кабатлана: арыслáндай йегет-иргә [Кандалый, 1988, б. 75]; бағ күзең йылтырыйдыр сулы чиләкти, аwызың җәйрәгән иске иләкти [Кандалый, 1988, б. 106], Түгәрәк алмадай башың, Қаләмдәй сызылған кашың [Кандалый, 1988, б. 118]; сандугач-былбылдай кеше сайрыйдыр аwаз илә [Кандалый, 1988, б. 133] һ.б.

Шулай итеп, XIX гасырның беренче яртысында иҗат ителгән шигъри әсәрләрнең авторлары, кайсы укучыны күз алдында тотып, нәрсә турында язуларына карап, төрки телнең аристократ-абруйлы һәм халыкчан варианты белән иҗат итәләр. Әлеге үзенчәлек сыйфатларны куллануда да чагылыш таба, абруйлы төркидә гарәп һәм фарсы алынмалары, халыкчан төркидә җанлы-сөйләмә һәм авыз иҗатына хас булган сыйфатлар кулланыла. Г. Кандалый иҗатында әлеге төрләрнең бер үк авторда файдаланылуы күзәтелә.

XIX гасырның икенче яртысында иҗат ителә торган поэзия әсәрләрендә сүз кулланылышы (шул исәптән, сыйфатлар да) авторның кем турында, нинди максат белән язуына туры китерелеп сайланып кулланыла.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә (1892) Шиһабетдин Мәрҗанинең физик халәтен, килешкилбәтен, тышкы кыяфәтен, акылын һәм аларның дәрәҗәсен сурәтли торган исемнәр белән бергә, сыйфатлар да эзлекле кулланыла: ...сүз қузғар ул ир асыл кирәк йирдән, Ходаем фирасәтле йөрәк биргән, ...чықарды татлы суны тирән йирдән, болағы саф [Акмулла, 1892, б. 2]; инсафлы урыс күрсә инанғандай, ул бер фазыйль ғалләмә, хаззы бар

дәрәҗә-и иҗтиһаддан, сүзе баһир, ...хәленә қале шаһид көндәй заһир, мәғрифәт-ел-риҗалидә [Акмулла, 1892, б. 3]; ...өстемдә керле күлмәк, йыртық дамбал, ...Мәргәнгә Ходай бирсә туры (توری) сәһем, Аңа булса мөқарин туры (توری) фәһем [Акмулла, 1892, б. 4] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, тамыр һәм ясалма асыл сыйфатлар белән бергә, эзлекле рәвештә, нисби-изафә сыйфатларның да кулланылуы күзәтелә. Шул рәвешле Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең эшчәнлеге тиешле югарылыкта тасвирлана.

Әлеге үзенчәлек, төснең һәм тәмнең билгесен белдерә торган татар теленең үз сыйфатлары белән ныгытыла бара, болар, гадәттә, күчерелмә мәгънәдә, ягъни троплар буларак кулланыла: Қайнар сөткә сары майны тамызған ул, чықарды татлы суны тирән йирдән, болағы саф [Акмулла, 1892, б. 2]. Бу юнәлештә, Мәрҗанигә каршы куела торган персонажларның, шул исәптән, авторның үзенең дә, җанлы сөйләмә сыйфатлар белән сурәтләнүе күренә: аңынаусыз, анау-монау кеше [Акмулла, 1892, б. 2] һ.б.

Текстларда *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльдән күчкән нисби сыйфатлар да эзлекле кулланыла: ...йөргән җирем қазақның бадиясе, ...утырған урыным – бер қаз ойасы, ... Бохар чықған мулла икәнсең [Акмулла, 2001, б. 39]; әсхабләр безгә салып киткән эз бар, ... сез қараған китапны без қарыймыз, қарышып йатқан бер малаймыз [Акмулла, 2001, б. 41] һ.б.

Кайбер сыйфатлар процессның билгесен белдереп хәл функциясендә файдаланыла: Мөселманға қарышуға ляиқ имәс [Акмулла, 1892, б. 3]; ...җан айамай қаршы торыб [Акмулла, 1892, б. 3]; ...йәтим қалдым [Акмулла, 1892, б. 4] һ.б.

Аңлашылганча, XIX гасыр башында һәм ахырында иҗат ителгән поэзия әсәрләрендә сыйфатның, гарәп-фарсы һәм төрки-татар телләренә хас булган, асыл һәм нисби төрләре файдаланыла. Авторларның һәм уңай, һәм кире эмоциональ кичерешләре тасвир ителгәндә, туры һәм күчерелмә мәгънәләре төп чара булып торалар.

Г. Тукайның башлангыч чор иҗатында язма традиция дәвам ителә, гомумтөркигә хас булган сыйфатлар файдаланыла, болар белән бергә, сөйләмә телгә хас булган сыйфатлар әдәбиләштерелә. «Г. Тукай. Шигърият теле. Сүзлек» (2009) хезмәтендә, шагыйрь файдаланган башка тел берәмлекләре кебек үк, сыйфатлар да сүзлек таләп иткән тәртиптә системага салынып бирелә. Сыйфатларның кабатлану ешлыгы төгәл күрсәтелә. Сүзлектә системага салынган байлыкны, бу урын-

да, сәнгать чарасы буларак файдаланылуына нигезләнеп барларга тиеш булабыз. Мәсәлән, *аwыр* сыйфаты авторның шигъри әсәрләрендә 11 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 31]. Шуларның бишесе, предметларның микъдарын белдереп, туры мәгънәсендә кулланыла дияргә мөмкин, әмма әсәр эчтәлегендә алар да өстәмә мәгънә ала: ...Киләрәхәт җиңеллекләр: хәлас булам аwыр йөкдин [Тукай, 1985, б. 208]; ...аwыр ул гер кеби [Тукай, 1985, б. 296], ...аwыр ул қурғашыннан [Тукай, 1985, 2, б. 29]; ...бик аwыр һәм озын басқыч [Тукай, 1985, б. 138]; ...аwыр штыклы солдат [Тукай, 1985, б. 249]. Шул ук сыйфат 7 мәртәбә образлы-күчерелмә рәвештә файдаланыла: ...Аwыр тау төсле йәнчер ул, басар ул [Тукай, 1985, 2, б. 192]; ...күтәрәм мин, қарт булсам да, аwыр тауны [Тукай, 1985, б. 212]; ...Йөкләдем мин бик аwыр зәхмәт сиңа [Тукай, 1985, б. 266]; ...мин бик аwыр хәлләргә калдым [Тукай, 1985, б. 287]; ...инде хәзер аwыр эшләр муйында юк [Тукай, 1985, 2, б. 58]; ...анда қалды тик аwыр хәсрәт, ачы қайғы [Тукай, 1985, 2, б. 65] һ.б.

*Ак* сыйфаты, төрле сүзформалары белән, 62 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 39–40]. Шуларның күбесе, табигать күренешләренә бәйле рәвештә, аерым предметларның, чәчкәләрнең, кошларның төсен белдерә: ...Чаналар астында, Ақ қарлар шытырдый [Тукай, 1985, б. 32]; Озақ тормас, килер ақ тунлы қыш та [Тукай, 1985, б. 110]; Ақ, қызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр [Тукай, 1985, б. 168] һ.б.

Табигый билге кешене, аның кыяфәтен, лирик геройның хис-кичерешләрен тасвир итү чарасы буларак файдаланыла: ...Пак хатын – судан, дәхи дә сөттән ақ [Тукай, 1985, б. 77]; Ақ қулыннан тотыйм, тотыйм, җибәр диеп [Тукай, 1985, б. 178]; Күр йөзеңне: нинди нурлы, нинди алсу, нинди ақ [Тукай, 1985, б. 180]; Қарап күрсә: йөзе нурлы бер аппақ бүрекле қарт, Җитен төсле сақалы ақ, кыйәфәтчә күрекле қарт [Тукай, 1985, б. 291] һ.б. Бу юнәлештә, *ак* сүзе абстракт һәм конкрет мәгънәле сүзләр белән, «логик төшенчәдән тыш метафорик төшенчәгә ия булган...» образлы сүз тезмәләре [Җәләй, 2000, б. 57] хасил итеп киң файдаланыла: ...ақ күңелдән саф көенчә [Тукай, 1985, б. 160]; Ақ күмәч берлән ашарлық саф һаwа [Тукай, 1985, 2, б. 215]; Хөр заман ақ қул белән күкләрдә йолдыз чүпләдем, Ақ күгәрченне қулымнан алдылар, қозғын биреп, Ақ кирәк дип, пақ кирәк дип күпме күз йәш түкмәдем [Тукай, 1985, 2, б. 218] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, образлы-күчерелмә мәгънәле тезмәләр, авторның һәр әсәрендә

сурәтләнә торган сәнгати фикерне укучыга камил рәвештә ирештерә торган чара буларак кулланыла.

Бу очракта *ак* әледән-әле *кара* сыйфатына каршы куела: Қараны йаз қара диб һәм иғтираф ит ақны ақ [Тукай,1985, б. 56]; Айырып ақны қарадан [Тукай, 1985, б. 216]; Сүз дәшүче йуқ иде, мин бер қараны ақ дисәм [Тукай, 1985, б. 246] һ.б.

Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә *ак* сыйфаты кебек үк *кара* сүзе дә, асылда, образлы-тасвирый тезмәләр буларак файдаланыла: Бәдбәхет, йөзе қара, бер җалмавыз [Тукай, 1985, б. 76]; Кирәксә, йәш җиренә қара қан сық [Тукай,1985, б. 94]; Қара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр [Тукай, 1985, б. 186] һ.б. Шуның белән бергә, *кара* сыйфаты да табигать күренешләрен, төс-кыяфәтне сурәтләү өчен дә кулланыла: Алсу йөзле, қара қашлы, қара күзле қызларын [Тукай, 1985, б. 169]; Абый белән бергәләшеп қара җирне [Тукай, 1985, 2, б. 51]; Ул қаты йоклый, вөҗүден қара туфрақ қаплаған [Тукай, 1985, 2, б. 69] һ.б.

Г. Тукай әсәрләрендә башка сыйфатлар да кулланыла. Мәсәлән, *ачы* сыйфаты 21 мәртәбә файдаланыла [Тукай, 2009, б. 76]. Мисаллардан аңлашылганча, ул туры-төп мәгънәсенә караганда, образлы-күчерелмә мәгънәләрдә ешрак кабатлана: Ачы булғач күңлем, шиғрем ачы чыға [Тукай, 1985, б. 176]; Қаты қайғы, ачы хәсрәт эчемдә [Тукай, 1985, б. 190], Шунда тамсын күз йәшемнең иң ачы һәм татлысы [Тукай, 1985, 2, б. 180] һ.б. *Татлы* сыйфаты 5 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 166]: Йаратам тәмле, татлы сүзеңезне [Тукай, 1985, б. 95] һ.б. *Тәмле* – 23, *тәмсез* – 3 мәртәбә файдаланыла [Тукай, 2009, б. 175]: Һәр тарафқа тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр [Тукай, 1985, б. 168]; Тәмле җимешләр эчендә тәмлесе – пилмән генә [Тукай, 1985, б. 218]; Тәмсез ачы сүзләр миңа йаwа иде [Тукай, 1985, б. 202] һ.б.

*Бай* сыйфаты 55 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, б. 103]: ...Бу сәхи, бер бай кеше тәкмил итәр барын дисәм [Тукай, 1985, б. 188] һ.б. Әлеге сүз сыйфатламышыннан башка еш кабатлана: Бер теләнчене қочақлашқан күреп бер бай белән [Тукай, 1985, б. 259] һ.б. *Бул* ярдәмлеге белән хәбәр вазифасын үти: Күршеләр бай булды [Тукай, 1985, б. 83]; Һич һөнәрсез бай булачақлар имеш [Тукай, 1985, б. 269] һ.б. *Вакытында, чагында* сүзләре белән вакыт хәлен белдерә: Сине бай wақтыңда, Дустларың мақтады [Тукай, 1985, 2, б. 31]; Бай чағында көлгүче [Тукай, 1985, 2, б. 39] һ.б. *Ярлы* сыйфатына каршы куела: Син бүген бай, бәлки шәйтаннан да йарлы иртәгә [Тукай, 1985, 2, б. 92] һ.б.

*Йарлы* сыйфаты 6 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 387]: Йарлыға биргән кеби ул җиккән ат [Тукай, 1985, 2, б. 214] һ.б.

*Биек* сыйфаты предмет билгесен белдереп, 4 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, б. 166]: Тау башына менеп кычкырмақчы булсам, Биек җир бит, еғылырмын дип шүрләп қалам [Тукай, 1985, б. 176] һ.б.

*Бөек* сыйфаты, затларның билгесен белдереп, 3 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 182], алынма *гали* сүзе белән чиратлаша: Мөкаддәс ул, бөек зат ул, ғали зат ул [Тукай, 1985, б. 172] һ.б. *Гали* сыйфаты 18 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 228–229]. Бөек мәгънәсендә һәм предмет, һәм затны ачыклый: Мәхәлле нәшре ғали җай шәһәрдер [Тукай, 1985, б. 34]; Қаләм ғали, каләм сами Қаләмдер [Тукай, 1985, б. 49]; Телим булырға мин инсане ғали [Тукай, 1985, б. 120] һ.б.

*Түбән* сыйфаты төрле сүзформалары белән, төрле вазифа үтәп, 21 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 215–216]: Уғрашып торма җиһанда иң түбән мәхлук белән. Әлеге сыйфат *сәфил* алынмасы белән чиратлаша: ...Та әзәлдән ул сәфилләр үз-үзеннән бетмәдә [Тукай, 1985, 2, б. 12] һ.б.

*Югары* сыйфаты 4 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, б. 361]: Йуғары мәртәбә килде [Тукай, 1985, 2, б. 22] һ.б. *Олуг* сыйфаты 13 мәртәбә файдаланыла: Дәгел мийаман олуғ шайаларға лаиқ [Тукай, 1985, б. 37] һ.б. *Зур* сыйфаты 78 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 320]. Абстрактлы сүзләр белән белдерелә торган төшенчәләрне чама ягыннан билгесен белдерә: ...Милләтә сәрмәя һәм зур мал ирер [Тукай, 1985, б. 27]; Мондый зур ниғмәтләре тәқдир кирәк [Тукай, 1985, б. 28]; Бетсен иде шул сары йөз – шундадыр зур қурқыныч [Тукай, 1985, б. 174] һ.б. Предметларның күләме ягыннан билгесен белдерә: Алар артында зур таулар ағара [Тукай, 1985, б. 191] һ.б. Аерым затларның дәрәҗәсен билгели: Бер заманда, шөбһәсез, бу күл кибәр, Дип ғақыллы зур хәкимнәр сөйлиләр [б. 269] һ.б. *Кечкенә* сыйфатына каршы куела: Зурмы дисәң, зур түгелдер, бу аwыл бик кечкенә [Тукай, 1985, б. 168]; Кечеләргә итеп шәфқәт, үзеннән зурға йул бирсә [Тукай, 1985, б. 80]; Доғамны тыңлый йолдызлар – кечесе, зурлары бергә [Тукай, 1985, 2, б. 14].

*Гали* сыйфаты белән чиратлашып, *гүзәл* сыйфаты кулланыла, 28 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 239–240]: Кәл, гүзәл, гарз ит җәмалың..., И гүзәл, кәл қаршыма, кәл, кыл тәбәссем лотфы идеб [Тукай, 1985, б. 68]; Кәнде хөснендән хәбәрсез бер гүзәл чуҗык кеби [Тукай, 1985, б. 84]; Қышта очқан күбәләк төсле гүзәл қызлар миңа [Тукай,

1985, 2, б. 265]; гүзәл ахшам [Тукай, 1985, б. 126]; гүзәл көннәр [Тукай, 1985, б. 231]; гүзәл исле чәчәкләр [Тукай, 1985, 2, б. 135] һ.б.

XIX гасырның икенче яртысыннан иске татар телендә төрле жанр-стильдә иҗат ителә торган проза әсәрләре алгы планга чыга. Поэзия әсәрләре белән чагыштырганда, башка сүз төркеменә караган сүзләр кебек үк, сыйфатларны да, табигый халәтенә якынайган хәлдә өйрәнергә, аларның нинди функция үтәүләрен төгәлрәк билгеләргә мөмкинлек ачыла.

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, татар сәнгатьле чәчмә әсәрләрен, вакыйга-хәлләрнең ничек итеп хикәяләнүенә карап, өч төрле тармакка бүлеп тикшерергә мөмкин булуы күренә. Сүзне сәнгатьле чәчмә әсәрләре риваять сөйләүче равилар исеменнән хикәяләнә торган К. Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы» (1868) һәм «Әбүгалисина кыйссасы» (1881), Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Бүз йегет» (1874) һәм «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1879) әсәрләре, Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы» (1887) кыйссаларыннан башларга туры килә. Әлеге әсәрләр, махсус рәвештә, татар укучылары укып аңласын дигән максатны күздә тотып тәрҗемә ителә. Димәк, сыйфат сүз төркеменә караган сүзләр дә, нигездә, сөйләмә телдәгечә файдаланыла. Әмма теләсә кайсы дәвердә иҗат ителә торган әдәби әсәрнең язма традициягә нигезләнүе мәгълүм булганга, гарәп-фарсы алынмаларыннан файдалануның дәвам ителүе күтелә.

Сәнгатьле чәчмә әсәрләрдә кулланыла торган сыйфатларны, тезмә әсәрләрне, тикшергәндәге кебек үк, хәзерге татар әдәби телендә анализлана торган лексик-семантик төркемнәргә нигезләп бүлеп өйрәнергә мөмкин [Татар грамматикасы, 2002, б. 66; Хисамова, 2006, б. 118–119]. Ләкин әдәби әсәрләрдә, шул исәптән, иске татар телендә язылганнарында да, авторның персонажларына карата мөнәсәбәтенә бәйле хәлдә, аларның 1) табигате-холкы, 2) физик халәте, килеш-килбәте, тышкы кыяфәте, 3) акылы-тәрбиясенең дәрәҗәсе, күләм-чамасы тасвир ителү барышында мәгълүмат бирелә, димәк, беренче чиратта, шушы юнәлештәге сыйфатларга игътибар итәргә кирәк була. Төс һәм тәм ягыннан билге белдерә, сизү-тою аша беленә һәм предметларның формасын, зурлыгын, күләмен күрсәтә торган сыйфатларның барысы да кешене сурәтләү уңаенда файдаланыла.

К. Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы»нда (1868), аерым персонажларның холкы-табигате, тышкы кыяфәте, тәрбия-акыл дәрәҗәсе вәзирләрнең һәм хатын сөйләме рәвешендә бирелгән хикәятләрдә

ачыла. Сүз башланганда, патшалар уңай яктан характерлана, аларның бөеклеге *олуг, асыл* сыйфатлары белән белдерелә: Ханқыйун исемле бер олуғ патша бар иде [Насыйри, 1975, б. 221]; Мисыр шәһәрендә бер олуғ патша бар иде [Насыйри, 1975, б. 245]. *Олуғ* сүзе, шул ук мәгънәдәге гарәп алынмасы шәһири (данлыклы, атаклы) сыйфаты белән чиратлаша, ягъни дәрәҗәнең тагын да югары булуы белдерелә: фирасәттә (зирәклектә) қамил булып, шәһири йарлық вә солтанәт анда бар иде [Насыйри, 1975, б. 221]. Димәк, поэзиядәге кебек үк, чәчмә әсәрләрдә дә, төрки-татар сүзе белән белдерелгән сыйфат мәгънәсенең тагын да өстенрәк булуын аңлату өчен, гарәп-фарсы алынма сыйфатлары файдаланыла. Хикәяләү барышында хатынның, вәзирләрнең, башка персонажларның характеры, акыл һәм белем дәрәҗәләре аларга карата булган мөнәсәбәтләрдә ачыклана бара. Бу сыйфатларның кайберләре исемләшә һәм эндәш сүз буларак кулланыла, яисә эндәш исемнең сыйфатын белдерә: И җанымдан артық ғазизем... [Насыйри, 1975, б. 224] һ.б.

К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда (1881), «Кырык вәзир кыйссасы»ннан аермалы буларак, әсәрдә бара торган вакыйга-хәлләрне аерым кешеләр сөйләми, хәбәр сөйләүчеләр һәм әсәрләрне күчерүчеләрнең фикере булуы искәртелә һәм тоташ дәвам ителә, «...гарәп-фарсы аз белгән адәмләрдән кыйсса вә хикәят укырга ихласы бар кешеләр өчен» тәрҗемә ителүе махсус ассызыклана [Насыйри, 1898, б. 3; 1974, б. 208]. Әлеге үзенчәлек Әбүгалисинаның зирәк акылын һәм аның дәрәҗәсен сурәтли торган сыйфатларның кулланылышында да чагылыш таба: «...Әбелхарис бераз аwыррак зиһенле бала иде. Әмма Әбүгалисина шул қадәр зирәк вә үткен зиһенле чапақ бала иде ки, тәғбир мөмкин түгел. Мәҗлесләрдә вә сохбәтләрдә фәһем вә фирасәте белән, вә үткенлеге белән қылны қырыққа йарыр иде» [Насыйри, 1898, б. 4]. Китерелгән өзектән күренгәнчә, Әбүгалисинаның акыл дәрәҗәсен күрсәтү өчен, борынгы төрки *сәргәк (зирәк)* [Әхмәтҗанов, 2005, б. 202] һәм татар теленең *үткен* сыйфаты, гарәп теленең зиһен (ذهن), хәтер, аң дигән исеменнән [Гарәпчә-татарча..., 1965, б. 132] *-ле* кушымчасы белән ясалган *зиһенле* сыйфатын, фарсы теленең чабек (چابك) (өлгер, җитез, җиңел, тиз, чапкын) сыйфатының [Гарәпчә-татарча..., 1965, б. 695], каргалы, богырыслан сөйләшләрендәге сәләтле, телгә оста, зирәк, минзәлә, эстәрлебаш сөйләшләрендәге телгә, сүзгә оста мәгънәләрендә [Татар теленең..., 2009, б. 729] кулланыла торган *чапак* (چاپك)сыйфатларын файдалана [Насыйри, 1896,

б. 4]. Бу сыйфатлар белдергән мәгънә алга таба гарәп теленең *фәһем* (فهم)(аң, аңлау, төшенү) һәм фирасәт (فراست) (сизгерлек, зиһенлелек) кебек, татар теленең *үткенлек* дигән исемнәре белән, тагын татар теленең шул ук мәгънәдәге *кылны кырыкка ярыр иде* дигән фразеологик әйтеме белән ныгытыла. Хикәяләү барышында Әбелхарис белән Әбүгалисинаның зирәклеге төрле вакыйга-хәлләрдә тасвир ителә, баштан ук Әбелхарисның авыррак зиһенле булуы искәртелә.

«Кырык вәзир кыйссасы»ндагы кебек үк, Әбелхарис белән Әбүгалисинаның акыл дәрәҗәсе, сөйләүче тарафыннан да әйтелергә, аерым персонажлар сөйләме рәвешендә белдерелергә дә мөмкин, бу очракта, сыйфатлар, асылда, эндәш сүз, мөрәҗәгать итү чарасы буларак та файдаланыла: и ғалиме зу фөнүн, и хикмәт иясе дана, и хәкиме хикмәт шинасе (حكيم حكمت شناس) [Насыйри, 1974, б. 216]; и мәхбүбе җиһан [Насыйри, 1974, б. 218]; и хикмәт вә Камал иясе [Насыйри, 1974, б. 227] һ.б. Күренгәнчә, мактау өчен гарәп вә фарсы алынмалары файдаланыла.

Персонажларның уңай һәм тискәре яктан тышкы һәм эчке сыйфатлары бирелгәндә алынмалар төрки-татарның үз сүзләре белән чиратлаштырыла: «Кырык вәзир»дә: Хак Тәғәлә хәзрәтләре аңа бер сөекле вә мәхбүб уғыл бирде, зифа буена қараса [Насыйри, 1975, б. 221]; күркәм сыйфатлары [Насыйри, 1975, б. 222]; һәйбәт гүзәл қыз [Насыйри, 1975, б. 222]; йәш хатынмын, атаң қартдыр, инсафсыз уғылың [Насыйри, 1975, б. 224]; олуғ wәзирлектә [Насыйри, 1975, б. 225]; надан wәзир, галим wәзир [Насыйри, 1975, б. 225]; ғайәт гүзәл хатын [Насыйри, 1975, б. 238] һ.б.

«Әбүгалисина»да: ахмақ, надан, батыйл падишаһ [Насыйри, 1974, б. 213]; һәйбәт гүзәл егетләр [Насыйри, 1974, б. 215]; аwазсыз, телсез (егетләр) [Насыйри, 1974, б. 215]; үткен вә җиңел бәдәнле, вә куwәт иqосе ғайәт зирәк йегетләрдер [Насыйри, 1974, б. 217]; гүзәл дөхтәре, гүзәллектә вә зифалықта нәзыйре йуқдыр [Насыйри, 1974, б. 217] һ.б.

Текстларда күпсанлы предметларларның, корылмаларның, урынчалыкларның формасын, зурлыгын, күләмен, төсен һ.б. якларыннан билгесен белдерә торган сыйфатлар кулланыла. «Кырык вәзир»дә: йаланғач қылыч [Насыйри, 1975, б. 222]; аулақ бүлмәсе [Насыйри, 1975, б. 225] һ.б. «Әбүгалисина»да: олуғ бина, олуғ хаммам, чилтақ үзә бер хаммам [Насыйри, 1898, б. 8]; зифа мишә ағачы [Насыйри, 1975, б. 215]; аулақ йир [Насыйри, 1898, б. 10]; тәғәҗҗеб вә ғыйбрат-

намә хаммамнар [Насыйри, 1975, б. 215]; күк мисале биек рәwaқлар (түшәмнәр), шәдади сөфәләр [Насыйри, 1974, б. 224] һ.б.

Төс, тәм, ис, матур сөйләү ягыннан билгене белдерә торган сыйфатлар тасвирны камилләштерә. «Кырык вәзир»дә: қызыл қанға буйалып утырыр [Насыйри, 1975, б. 224]; зәһәре һәляһил [Насыйри, 1974, б. 226] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: туфрақлары ғанбәр, һаwасы мөләем [Насыйри, 1974, б. 224]; кибет бик нәфис һәйбәт, вә һәм хәлwә бик нәфис ширин вә татлы [Насыйри, 1974, б. 23]; мәхәббәт амиз кәлимәләр [Насыйри, 1974, б. 236] һ.б.

Шулай итеп, К. Насыйри иҗатында, сыйфатның барлык лексик-семантик төркемчәләре дә файдаланыла. Аларның, хәзерге әдәби телдәге кебек, лексик-грамматик мөмкинлекләрен күзәтеп була.

Асыл-тамыр сыйфатлар. «Кырык вәзир»дә: бер олуғ падишаһ бар иде [Насыйри, 1975, б. 221]. *Олуғ* сүзе, олы дип язылыштагы пары белән чиратлаша: бер олы патшаның қызын алып, қадим заманда бер олы патша бар иде, элгәре заманда бер олы патша бар иде, олуғ уғлан [Насыйри, 1975, б. 222, 230, 231, 234, 239]. Шуның белән бергә, *олуғ* сүзе абстракт төшенчәләрнең билгесен белдереп тә кулланыла: олуғ қаза күрер [Насыйри, 1975, б. 222]; олуғ зыйафәт қылды [Насыйри, 1975, б. 249] һ.б.

Димәк, *олуг* сүзенең хәзерге татар телендә иске китап искәрмәсе белән бирелә торган һәм *олуглау, олуглык, олуглыклы* формаларында, югары дәрәҗәдәге затларның гына бөеклеген, мәртәбәлелеген, аларны хөрмәтләү, ихтирам итүне белдерү мәгънәсе бу вакытта әле тотрыкланмаган дип әйтергә тиеш булабыз. *Олы* синонимы үзенең антонимы белән парлашып, исемләшеп тә кулланыла: олы-кече арасында мәшһүр булып [Насыйри, 1975, б. 222] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда да асыл-тамыр сыйфатлар яратып кулланыла: игез ике бала, зирәк, чапак [Насыйри, 1974, б. 208]; надан, тупас балалар [Насыйри, 1974, б. 209]; надан адәм, надан падишаһ [Насыйри, 1974, б. 213]; гүзәл егетләр, олуқ бина, олуғ хаммам [Насыйри, 1974, б. 215]; фәсыйх телен [Насыйри, 1974, б. 218]; аулақ хөҗрәмә [Насыйри, 1974, б. 219] һ.б. Күренгәнчә, *олуг* сыйфаты, хәзерге әдәби телдән аермалы буларак, җанлы затларны гына түгел, предметларны да, аерым күренешләрне дә билгеләп кулланыла, *зур* сыйфаты белән чиратлаша башлый.

Асыл-ясалма сыйфатлар. «Кырык вәзир»дә: wазыйфасыз адәм булмас, wазыйфасыз адәмләр сорадың, кияү мөрәүwәтле, назәнин кыз [Насыйри, 1975, б. 230]; қыйммәтле киемнәр, хисапсыз алтын вә ташлар күрсәтте [Насыйри, 1975, б. 233]; бәхетсез башым [Насыйри, 1975, б. 246] һ.б. «Әбүгалисина»да: зиһенле, үткен [Насыйри, 1975, б. 208]; кечкенә-кечкенә баwырсак [Насыйри, 1975, б. 212]; ғаҗәиб сурәт [Насыйри, 1975, б. 213]; гөнаһсыз, дәғwәсез, ул мазлум бичараларга [Насыйри, 1975, б. 213]; мәғнәсез хәрәкәт [Насыйри, 1975, б. 214]; эче-тышы хыйәнәтсез туғры фәһемле адәм иде [Насыйри, 1975, б. 217]; қыйммәтле һәдияләрен [Насыйри, 1975, б. 219] һ.б.

Асыл сыйфатлар дәрәҗә белән төрләнеп кулланыла. «Кырык вәзир»дә: аwызы туп-тулы қан булды [Насыйри, 1975, б. 224] һ.б. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: олуғрак шәкертләреннән [Насыйри, 1974, б. 209] һ.б.

Асыл сыйфатларның күбесе исемләшә, сыйфатланмышыннан башка килгән сыйфат, исем кебек үк, төрләнә башлый, төрле заттагы тартым һәм килеш кушымчалары белән кулланыла. «Кырык вәзир»дә: Гүзәллектә вә зифалықта нәзыйре йукдыр [Насыйри, 1975, б. 217]; җиһан халқы аның күркәмлегенә вә җәмаленә ғашыйқ иде [Насыйри, 1975, б. 221], уғры туғрыға хиш булмас [Насыйри, 1975, б. 230]; ғаделлегем заһир булса Насыйри, 1975, [б. 247] һ.б. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: йәшнең һәр хәлдә бер хөкеме бардыр [Насыйри, 1974, б. 209]; шәһәрнең изгеләре вә ғалимләре белән танышып [Насыйри, 1974, б. 209]; аларның йаwызлықларыннан [Насыйри, 1974, б. 213]; олуғларын вә баһадирларын җыйдырды [Насыйри, 1974, б. 249] һ.б.

Нисби сыйфатларның кулланылышы. «Кырык вәзир»дә: туғрылық йөзеннән [Насыйри, 1975, б. 223]; атлы, җәяүле ғаскәр сурәте [Насыйри, 1975, б. 226]; җанлы чын-чын ғаскәр [Насыйри, 1975, б. 226]; җансыз wазыйфасыз ғаскәр булмас [Насыйри, 1975, б. 232]; сарымсақлы аш [Насыйри, 1975, б. 234]; хорасанлы кеше [Насыйри, 1975, б. 236]; хыйәнәтле wәзирләр [Насыйри, 1975, б. 244] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: қоббәле хаммам [Насыйри, 1974, б. 215]; дәүләтле башыңыз өчен, и шаһым әфәнде [Насыйри, 1974, б. 218]; хисапсыз ғаскәр [Насыйри, 1974, б. 230]; зәғфранлы биш бармақ [Насыйри, 1974, б. 242] һ.б.

К. Насыйриның кыйссаларында асыл һәм нисби сыйфатлар белән рәттән, хәзерге татар телендәге кебек үк, аерым фигыльләрдән күчкән сыйфатларның кулланылуы да күзәтелә.

«Кырык вәзир»дә: җиткән йегетсең, фәна дәрәҗәсенә җиткән қартдыр [Насыйри, 1975, б. 223]; сөйгән йегете [Насыйри, 1975, б. 228, 229]; җыйған малымны [б Насыйри, 1975, б. 231]; булыр-булмас җирдә ойат килерлек булса [Насыйри, 1975, б. 237] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: торышыр вә бәхәс қылышыр кеше қалмады [Насыйри, 1974, б. 209]; ағар чишмәләр вә һәйбәт көтепханәләр [Насыйри, 1974, б. 212]; ағачтан төзелмеш бер йегет [Насыйри, 1974, 216, 217] ағар чишмәләр [Насыйри, 1974, б. 224]; төзелмеш бакчасына [Насыйри, 1974, б. 225]; күндерелмеш һәдийәләрне [Насыйри, 1974, б. 243] һ.б.

Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, төрле лексик-семантик һәм лексик-грамматик төркемнәргә бүленә торган сыйфатларның, хәзерге татар телендәге кебек, асыл, нисби, тамыр, ясалма рәвешендә файдаланылуы аңлашыла.

Аерым сыйфатларның предмет билгесен генә түгел, эш-хәлнең билгесен дә белдереп, җөмләдә аергыч кына түгел, процессның билгесен белдерү функциясендә кулланылып, җөмләдә хәл дә була алулары мәгълүм. К. Насыйри кыйссаларында да, Г. Кандалый шигырьләрендәге кебек, яхшы һәм башка сыйфатларның, процессны белдерә торган сүз белән кулланылганда, эшнең үтәлү рәвешен (хәлен) белдерә торган мәгънәдә файдаланылуы аңлашыла. «Кырык вәзир»дә: йахшы, пақ итеп йуыгыз, йахшылап күмегез [Насыйри, 1975, б. 228], сәламәт қайтып кил, йалғыз үзе қалып, йалгыз утырғанда [Насыйри, 1975, б. 228]; йахшы иттең [Насыйри, 1975, б. 246] һ.б. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: бик йахшы сәүдә қыла башлады [Насыйри, 1974, б. 236]; булмаса йахшы иде [Насыйри, 1974, б. 239] һ.б. *Тугры* сыйфатының да һәм предмет, һәм процеес билгесен белдерү вазифалары белән кулланылуы күзәтелә. «Кырык вәзир» дә: уғры туғрыға хиш булмас, мин үзем туғры булғанлығым өчен [Насыйри, 1975, б. 230]; хәйләбез туғры килсен [Насыйри, 1975, б. 246] һ.б. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: бер базарға туғры килеп [Насыйри, 1898, б. 4]; гөлне алып туғры падишаһның сарак қапусына килеб [Насыйри, 1898, б. 73]; өйүнең янынннан узарға туғры килде [Насыйри, 1898, б. 76]; хаммамнан чыгып, туғры шаһның сарайына килде [Насыйри, 1898, б. 79].Мисаллардан

аңлашылганча, *туғры* сүзенең эзлекле рәвештә процессның билгесен белдереп, ягъни рәвеш буларак кулланылуы күзәтелә.

Кайбер очракларда сыйфатлар, җөмләнең гади хәбәре, ешрак тезмә хәбәре функциясендә файдаланыла. «Кырык вәзир»дә: акылы вә тәдбире зәғифтер [Насыйри, 1975, б. 223]; йахшырак булыр иде [Насыйри, 1975, б. 224]; ...wазифасыз булсын [Насыйри, 1975, б. 226]; йегет шат булып [Насыйри, 1975, б. 233] һ.б. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: ғаҗиз булғанлар иде [Насыйри, 1974, б. 213]; чарасыз қалғаннар иде [Насыйри, 1974, б. 213]; мәхкәм бәйләделәр, телсез йөрерләр, чарасыз ғаҗиз калып, ихтыйарсыз йығлады [Насыйри, 1974, б. 213] һ.б.

Шуның белән бергә, текстларда кайбер рәвешләр дә предметларның билгесен белдерү функциясендә файдаланыла. «Кырык вәзир»дә: аз нәфәқаға, аз wазыйфаға канәгать кылсыннар [Насыйри, 1975, б. 226] һ.б. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: аз заманда хәзер булып [Насыйри, 1974, б. 222] һ.б.

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, вакыйганы сөйләп хикәяләүнең беренче төрендә иҗат ителгән кыйссаларда, сыйфатның барлык лексик-семантик төркемчәләре һәм аларның лексик-грамматик мөмкинлекләренең кулланылуы күренә.

Алда әйтеп үткәнчә, татар әдәбиятында сәнгатьле чәчмә әсәрләрдә вакыйганы сөйләп хикәяләүнең икенче төре М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романы белән башлана (1886), З. Бигиев, Ф. Кәрими, Р. Фәхретдин, Г. Гафуров-Чыгтай, Ш. Мөхәммәдов, З. Һади кебек татар халкының танылган мәгърифәтчеләренең иҗаты белән дәвам ителә. Авторлар, риваять булып килә торган гомум билгеле хакыйкатьне түгел, чынбарлыкта булырга мөмкин хәлләрне укучысына эндәшәэндәшә үзе сөйләп бара. Әсәрнең нигезен автор сөйләме һәм укучы мөнәсәбәте тәшкил итә [Бәширова, 1979, б. 7–41]. Әлеге үзенчәлек персонажларның характерын, акылы, белемен, төс-кыяфәтен тасвирлауга тәэсир итә. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында төп персонажның төс-кыяфәтен тасвирлаудан алда, аның кем булуы, нәрсә эшләве, кайда, ничек торуы, аңа карата башка кешеләрнең нинди мөнәсәбәттә булуы турында мәгълүмат бирелә. Персонажны характерлау, кыйссалардагы кебек, *гүзәл, гыйлемле,* яисә *надан, ямьсез* дигән гомуми төшенчәләр белән башланса да, алга таба әлеге төшенчәләр тәфсилләнә, җанлы кешеләргә хас булганча, тәгаенләнеп сурәтләнә: «...Бу ханә үзе кечүк булса да, тахтадан башы, анбары вә мөхкәм сарайлары сахибенең иҗтиһадлы вә хезмәт сәвән адәм идегене күстерүрләр

иде… Йөзенә баксаң, бу йегерме биш йәшлек җегеткә тәғәҗҗебләнерсең. Йөзе гүзәл ачық. Йаңадан чықмыш кечүк сақалы вә мыйықлары вә кечүк саче қоңғыр рәңкдә улып, җәмаләтле йөзенең гүзәллегене дәһа зийадәләшдерүрләр. Нурлы вә күк күзләре сәтра бәсәтра сәхифәйе йөгереп кәчәйүрләр. Башында бархат тақйасының көмеш айы йалт-йолт ялтырар» [Акъегет, 1886, б. 2–4]. Китерелгән өзектән аңлашылганча, авторның һәр яктан уңай булган персонажны сурәтләгәндә, сыйфатларның бигрәк тә төрле форма һәм төс белдерә торганнарын яратып куллануы күренә. Хисаметдин менлага пар булачак Хәнифә туташның өстебашы тасвир ителгәндә, шундый ук сыйфатлар тагын да тәфсиллерәк файдаланыла: «Қыз урта буйлы, башында йахшы Қазан қалпағы кийелмеш, өстендәге йоннықы күк камзулы нәзек вә зифа буйына йахшы йақышыр. Муйынында саф көмеш монетлар бағланмыш, уфак-уфак атлап кәчән wақытда йомырық вә тағчық шикелле ике күкесенә ақчалар челдер-челдер орылыр, айағында тамбурлы читек-башмак, саче вә күзләре вә қашлары йалтыраwық қара, йөзе нурлы, қызғылт ақ, борыны кечкенә вә гүзәл. ... Бу нәзек бил вә җәмилә қыз менланың күзенә тәмамән күренде» [Акъегет, 1886, б. 9].

Алга таба персонажларның өсте-башы, кыяфәте кебек үк, аларның эчке дөньясы, акылы, фикер эшчәнлеге сурәтләнә. Бу очракта да күпсанлы предметларның, корылмаларның, урынчалыкларның формасы, зурлыгы, күләме сыйфатлар белән тасвир ителә. Тәм һәм ис ягыннан билге белдерүче сыйфатлар белән көчәйтеп җибәрелә.

Әлеге һәм башка лексик-семантик төркемгә карый торган сыйфатларны, лексик-грамматик төркемнәргә бүләргә һәм ясалышлары ягыннан традицион рәвештә асыл һәм нисби дип тикшерергә мөмкин.

Асыл-тамыр сыйфатлар: урамы озын вә киңдер, кечек ханә, мөхкәм сарайлары [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 45]; диле җаһилә, бушI сүзләренә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; қара иген эше [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; кечек сақалы, күк күзләре [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; тирән фикерә, бийек буйыны, ийү кыйәфәтене, хөсне мәғишәтене, бөйек бәлайа [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48]; ачық тупраклар, ғәҗәйеб сүзләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 49] һ.б.

Асыл-ясалма сыйфатлар: иҗтиһатлы адәм [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 45]; асылсыз сүзләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; җәмаләтле йөзе, нурлы күзләре [Татар мәгърифәтчелек..., 1979,

б. 46]; ихтыяҗсыз мәғишәт [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; дәүләтле кияү [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53] һ.б.

Асыл сыйфатлар аерым очракларда артыклык һәм кимлек дәрәҗәләрендә кулланылалар: байырак кешеләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50]; қып-қызыл дудақлары [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51]; кызгылт ак [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50] һ.б.

Асыл сыйфатлар исемләшә, исем кебек төрләнеп кулланыла: бу җәмиләйә бақыб [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50]; нийә Алла бөйлә җәмиләләр ярата икән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51]; җәһилемез йарамаслық итмеш [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53] һ.б.

Нисби сыйфатлар: қыйбла тарафындағы очында [Акъегет, 1886, б. 2]; ғосманлы җирендән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; вилайәтле бикләрдән [Татар мәгърифәтчелек..., б. 50]; тамбурлы читек-башмақ [б. 50], сезә аwыл қызы йақышмаз, сезә шәһәрле кирәк [Татар мәгърифәтчелек..., б. 52] һ.б.

Кайбер сыйфатлар процессның билгесен белдереп кулланыла: йахшы белмәдекләреннән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; сез йахшы қылдыңыз [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50]; хақы бераз артық алынса да [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50]; туғры әйтәсең [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 58] һ.б. Әлеге мисаллардан, алдагы әсәрләрдәге традиция дәвам ителеп, *йахшы* һәм *туғры* сүзләренең предметның билгесен белдерә торган аергыч һәм эшхәлнең билгесен белдерә торган хәл буларак файдаланылуларын күзәтә алабыз.

Аерым очракларда сыйфатлар, ярдәмче фигыльләр белән бергә, җөмләнең гади хәбәре, ешрак тезмә хәбәре функциясендә файдаланыла: ...бик ризықлы вә бәхтийәр улды [Татар мәгърифәтчелек..., 1970, б. 58] һ.б.

Шуның белән бергә *чуқ* рәвеше эзлекле рәвештә предметларның микъдари билгесен белдерү функциясендә файдаланыла: чуқ адәм, чуқ халық [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; чуқ йазык вә тәғәҗҗеп [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48]; чуқ кеше [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53] һ.б. *Күп* рәвеше исә артыклык дәрәҗәсендә кулланыла: күбрәк бармаға ғәдәтләнде, күбрәк киләсәң [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 57] һ.б.

З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими һ.б. әдипләрнең хикәя һәм романнарында кулланыла торган сыйфатларны да шушы тәртиптә, ягъни сыйфатның тел күренеше буларак табигатенә нигезләнеп тик-

шерүне дәвам итәргә мөмкин, әмма әсәрнең текст-сөйләм күренеше үзенчәлегенә игътибар итү зарур.

З. Бигиев романнарының икесендә дә җинаятьчелек белән бәйле вакыйгалар турында сүз алып барыла. Персонажларның төс-кыяфәте, килеш-килбәте, характер чалымнары шушы яссылыкта чагыла. «Өлүф..»тә (1887): Хатынның йәше йегерме ике, йегерме өчдән зийадә булмасқа кәрәк, үзе һәм сахибе җәмал [Бигиев, 1991, б. 222]; күрше 7 нче нумердәге қызны күрдем, ғайәт тә җәмилә улып, гимназиядә курс тәмам итмеш [Бигиев, 1991, б. 229]; «Нә қыйәфәтле, нә төсле?» – дәйү сорадықларында: «Нечкә адәм, озын буйлы, ақ йөзле, кечек сары сақаллы» – дәйү швейцар қыйәфәтене-төсене тәғриф кылдуғы... [Бигиев, 1991, б. 222]; ишекдән урта буйлы, қара сақаллы, озын қара сачле бер рус керде [Бигиев, 1991, б. 224]; Әхмәди бай алтмыш йәшләренә ирешмеш, ақ сақаллы, қалын-йуан кеше иде [Бигиев, 1991, б. 227]; господин Андреев бийек буйлы, озын қара сачле... [Бигиев, 1991, б. 228] һ.б. Мисалардан күренгәнчә, яшь кызның чибәрлеге *җәмилә* дигән асыл сыйфатны ике мәртәбә кабатлап, персонажларның өчесе дә бер үк сүзләр белән диярлек *-лы* кушымчалы ясалма сыйфат белән тасвир ителә. Сыйфат сүз төркеменә караган сүзләрнең файдаланылуы турындагы фикерне артык киңәйтеп булмаганлыгы аңлашыла. Сүз җебен саклау максатыннан *олуғ* һәм *йахшы* сыйфатларының ничек кулланылуына игътибар итәргә тиеш булабыз: йахшы аңлатмақ өчен [Бигиев, 1991, б. 221]; олуғ вә мөғтәбәр мөсафирханә [Бигиев, 1991, б. 221]; йахшы дөш күрмеш [Бигиев, 1991, б. 227]; дөшең йахшы [Бигиев, 1991, б. 228]; мән сезгә олуғ хезмәт илә килдем [Бигиев, 1991, б. 228] һ.б.

Ф. Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе» (1897) хикәясендә ямьле җәй фасылы, чибәр чегән кызлары хакында, персонаж тарафыннан I заттан сөйләнелә, димәк, эмоциональ хис-кичерешләр турыдан-туры, ачыктан-ачык белдерелә: Йулның ике тарафындағы сахралар хәтфә кебек йәм-йәшел үләнләр вә төрле-төрле ләтыйф чәчәкләр илә өретелмештер. Һәр нәүғы гүзәл вә ләтыйф күбәләкләр илә төрле-төрле чебеннәр вә қортлар, арлы-бирле очышып, сахраның гүзәллегене арттырмақта иделәр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224]; Анлардан бәғзан-бәғзан қара күзле, қара қашлы, әсмар рәңле бик гүзәл қызлар җитешә икән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224]; җиләк кебек пешкән қызыл йаңақлы, саф күзле аwыл күзләренең ләтафәт вә дилбәрлекне тәғриф итмәк кемнең қулыннан килер [Татар мәгърифәт-

челек..., 1979, б. 225] һ.б. Китерелгән өзекләрдән күренгәнчә, төрле лексик-семантик төркемгә карый торган сыйфатларны, лексик-грамматик төркемнәргә бүләргә һәм ясалышлары ягыннан традицион рәвештә асыл һәм нисби дип тикшерергә мөмкин.

Асыл-тамыр сыйфатлар: йәш wақытта, йәш килен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 220]; қоры туфрақ, йахшы ғына бер қарт, фәна вә яман ғәдәтләр, йәш wақытта, суфый вә тәқwә кеше [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 222]; гүзәл-гүзәл җаwаплар, озын манарасы, олуғ юл [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 223]; тар йуллар, төрле-төрле ләтыйф чәчәкләр, һәр нәүге гүзәл вә ләтыйф күбәләкләр, ләтыйф вә көмеш кебек саф бер су [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224]; гүзәл бер җир [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224]; хикәйәтнең қызық җирләре, қара күзле, қара қашлы, әсмәр рәңле, бик гүзәл қызлар [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224] һ.б.

Асыл-ясалма сыйфатлар: төрле-төрле хикәйәтләр, сөйемле вә бала-чағаларға бик мәрхәмәтле, тар табиғәтле вә холықсыз қайната, ләззәтле итеп йазылған җен хикәятләренә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 220]; тәүфиқлы, истиқамәтле бер қарт, хикәйәтнең иң тәмле җиренә, файдасыз бер эш [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 222]; хәwефле бер эшдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 223]; күңелләре күтәренке була [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 225]; әдәпле вә намуслы, дәртле йегет икәнлегемне [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 227] һ.б.

Дәрәҗә белән төрләнешләре: бик сөйемле, бик мәрхәмәтле [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 220]; йәм-йәшел үләнләр, шулқәдәр гүзәл вә шулқәдәр шағыйрәнә иде ки [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224] һ.б.

Асыл сыйфатларның исемләшүе: мутлар, найаннар, сезләр әле йәшләр, дөнйаның ачысыны, төчесене [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 222] һ.б.

Нисби сыйфатлар: қайыннар арасындағы күләгәлек йулдан, йулның ике тарафындағы сахралар [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224]; урманның буйындағы йулдан, атлы кешенең, арбалы ченкәнәләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224]; ғосманлы мөхәррир [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 225] һ.б.

Кайбер сыйфатларның процессның билгесен белдереп кулланылуы: зуррақ үсеп [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 220, 224]; йахшы җаwап бирсәк, җаwапны начар бирсәк [Татар мәгърифәт-

челек..., 1979, б. 223]; җиләкләр бигрәк гүзәл пешкән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 226]; бераз зур үскәч [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 229] һ.б.

*Күп* рәвеше, эзлекле булып, предметларның микъдари билгесен белдерү функциясендә файдаланыла: күп хикәйәтләр сөйли торған иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 220]; күп кешенең күңеле [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224]; күбрәк нәрсәләр өйрәнгән идек [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224]; күп адәм күреп кимсенмәйләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 225] һ.б.

Р. Фәхретдиннең сәнгатьле чәчмә әсәрләре дә авторның сөйләме рәвешендә хикәяләнә, димәк, табигать күренешләре, аерым персонажларның характеры-табигате, тәрбиясе, тышкы кыяфәте, акыл дәрәҗәсе һ.б. язучының үз карашы буларак тасвир ителә. Бу уңайдан хискичерешләр дә төгәлрәк ачыла, исемнәрнең билгесен белдерә торган сыйфатлар мулрак кулланыла. Аларны төрле лексик-семантик төркемнәргә бүлеп карарга һәм лексик-грамматик мөмкинлекләрен тикшерергә, синтаксик вазифаларын билгеләргә мөмкин. Асыл-тамыр сыйфатлар: Қазан – Русийә дәүләтендә олуғ бер шәһәрдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 264]; олуғ бүлемдә, олуғ вә гүзәл фәсад илә бина иделмеш, олуғ ислам мәдрәсәләре, ... бийек түбәгә бина иделмешдер, бийек манара [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 266]; олуғ эшем, олуғ бер ләззәтдер, ... холқы гүзәл улмаған кешене адәмләр сәүмәзләр, Аллаһы Тәғәлә бөйекдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, *олуг* сыйфатының эзлекле рәвештә предметның билгесен белдереп кулланылуы, *бийек* сыйфаты белән чиратлашуы күзәтелә.

Асыл-ясалма сыйфатлар: бездән мәғлүматлы вә үткен фикерле кемсәнәләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 264]; әһле ислам ғомумән дийәнәтле, тәқwә улып ғайәт тә пакизә вә тәмизләрдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 266]; дәғwәле вә үзләренә хөсне занлы идекеләре сүзләнмәктәдер, инсан қосурсыз улмас, зарарлы хәстәлек [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 266]; әдәпле, ғыйффәтле, сабырлы, тәхәммелле, ... бездән мәрхәмәтледер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267] һ.б.

Ф. Кәрими, Р. Фәхретдин әсәрләрендәге кебек, башка мәгърифәтчеләрнең иҗатында да сыйфатларның ничек итеп кулланылуын шушы тәртиптә тикшерергә мөмкин.

Сәнгатьле чәчмә әсәрләрдә вакыйганы образлап хикәяләүнең өченче төре классик әдипләрнең иҗаты белән башлана. Сыйфатларны куллануда алдагы чорлардагы традиция дәвам ителә. Асыл сыйфат-

ларның төрле лексик-семантик төркемчәләре файдаланыла, аларны тамыр, ясалма дип бүлеп карарга, дәрәҗәләрен билгеләргә, исемләшү-исемләшмәүләрен күзәтергә була. Нисби сыйфатлар төзелешләре буенча тикшерелә, бу юнәлештә тагын фигыльләрдән күчкән сыйфатларга, кайбер сыйфатларның процессның билгесен белдереп кулланылуына һәм, киресенчә, кайсы рәвешләрнең предметның да билгесен белдереп файдаланыла алуына игътибар итү сорала.

Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1899) хикәясен уку барышында, сыйфатларның табигатенә нисбәтән үзенчәлекләренең барысының да кулланылышта булуы күзәтелә. Асыл-тамыр сыйфатлар: зур фамилиядән, ғазиз балам, йахшы ғына бала иде [Исхакый, 1998, б. 31]; надан халық, ғалим кеше [Исхакый, 1998, б. 32]; йахшырақ мәдрәсәгә, ғалим кеше [Исхакый, 1998, б. 34]; кечкенә чақта, йаңа мәдрәсә, иске мәдрәсә [Исхакый, 1998, б. 35]; йахшы уқуына [Исхакый, 1998, б. 39]; матур өй [Исхакый, 1998, б. 42]; йәш-йәш үләннәрдән, хуш-хуш исләрдән, матур-матур ағачлардан, ғәҗәп-ғәҗәп қошлардан [Исхакый, 1998, б. 43] һ.б.

Асыл-ясалма сыйфатлар дигәндә, бу әдиптә *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчасы белән ясала торган сыйфатларны эзлекле кулланылуы күзәтелә: қурқынычлы таwышлар, моңлы манзара, кәйефсез wақытлар, рәхәтсез хәлләрне [Исхакый, 1998, б. 31]; зиһенсез бала, қадерле wақыт [Исхакый, 1998, б. 32]; үзе тәүфиқле [Исхакый, 1998, б. 34]; дөнйа-ахирәттә шатлықлы ғомерләр насыйп әйләсен [Исхакый, 1998, б. 35, 39], минем шул шатлықлы көнемдә [Исхакый, 1998, б. 36] һ.б.

Сыйфатларның дәрәҗә белән төрләнеше: йахшырақ мәдрәсәгә [Исхакый,1998, б. 34]; үткенрәк, тийешлерәк шәкертне [Исхакый, 1998, б. 35]; зуррақ мәдрәсәгә илтергә [Исхакый, 1998, б. 43]; зурраѓрак кешеләр дә сораѓаннар [Исхакый, 1998, б. 45] һ.б.

Нисби сыйфатларның да *-лы/-сыз* кушымчалары белән ясалуы һәм аларның «асыл сыйфатларга күчүе, яисә... мондый берәмлекләрнең кайберләрен асыл һәм нисби сыйфатлар арасында торган сүзләр дип карау да бар» [Хисамова, 2006, б. 117]. Г. Исхакый әсәрләрендәге кебек, ачыктан-ачык нисбәт төшенчәсе белдерелмәгәндә, рәттән диярлек тезелеп бара торган *-лы/-сыз* кушымчалы сыйфатларның дәрәҗә белән төрләнү-төрләнмәвен, исемләшә алуын билгеләргә кирәк була: wазыйфалы мөғәллим [Исхакый, 1998, б. 32]; бәдәлсез тәхсил итәрмен, ақчасыз қабул итәрләр, [Исхакый, 1998, б. 37]; хыйәнәтле көйемчә [Исхакый, 1998, б. 48]; хыйәнәтле бер қыз [Исхакый, 1998, б. 49] һ.б.

*-лы/-сыз* кушымчалы сыйфатлар *бул-* ярдәмче фигыле белән хәбәр вазифасында да кулланыла: минем шикелле бәхетсез булуларын исәплатеп [Исхакый, 1998, б. 31]; үзләре саwаплы булырлар иде [Исхакый, 1998, б. 33]; ул бик надан булып [Исхакый, 1998, б. 34]; бик йахшы булырға тырыш, бик тәүфыйқлы, бик әдәпле, бик ғақыллы бул [Исхакый, 1998, б. 42] һ.б.

Тотрыклы тезмә хасил итә: мине қулсыз қалдырып [Исхакый, 1998, б. 32] һ.б.

Аерым сыйфатлар процессның билгесен белдерә: бигрәк йахшы уқый икән [Исхакый, 1998, б. 33]; йахшылап утырығыз [Исхакый, 1998, б. 35]; бу арада аның эше бик күп [Исхакый, 1998, б. 40] һ.б. Авторның башка әсәрләрендә сыйфатлар кулланылышын шушы тәртиптә өйрәнергә мөмкин.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә (1907) асыл-тамыр сыйфатлар: йақты йөз, матур қойашлы көннәр, йәшел хәтфә [Ибраһимов, 1974, б. 399]; йахшырак урын, рәхәт вә йомшақ тәрбийәдә, бик чиста вә йахшы киемнәрдән, өлкән өйләрне вә адәмнәрнең [б. 400]; бик йахшы киемнәрене, өлкән вә матур йорт [Ибраһимов, 1974, б. 400]; бик қара, кечкенә-кечкенә тишек кийезләр, қап-қара тышлы мендәрләр, сары нәрсә [Ибраһимов, 1974, б. 401] һ.б.

Асыл-ясалма сыйфатлар: қойашлы көннәр, мәһабәтле вә ару кийемле булыр [Ибраһимов, 1974, б. 400]; тузанлы, чүпле, сулы, йәмсез өстәлләр [Ибраһимов, 1974, б. 401] һ.б.

Нисби сыйфатлар: соңғы көннәре [Ибраһимов, 1974, б. 399]; андағы йортлар [Ибраһимов, 1974, б. 400]; мәдрәсәдәге шәкерт вә мөғәллимнәр [Ибраһимов, 1974, б. 400] һ.б.

Аерым фигыльләрдән күчкән сыйфатларның кулланылуы да күзәтелә: торачақ мәдрәсәсене, без барачақ мәдрәсә, ташландық өй [б. 400] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, Г. Ибраһимовның бу беренче әсәрендә сыйфат сүз төркеменә караган сүзләрнең рәттән тезелеп баруы, төрле сыйфатларның бер үк җөмләләрдә кулланылуы, аларның эзлекле рәвештә диярлек *гаять, чиктән тыш, бик* рәвешләре белән ачыклануы, *өлкән* сыйфатының һәм зат, һәм предметларның билгесен белдереп кулланылуы күзәтелә.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» (1907, 1909) хикәясендә, асыл-тамыр сыйфатлар: матур татар қызы [Әмирхан, 1984, б. 12]; ләтыйф қайғы [Әмирхан, 1984, б. 16] һ.б.

Асыл-ясалма сыйфатлар: ләззәтле таwышы [Әмирхан, 1984, б. 12]; шатлыкълы гайет көне [Әмирхан, 1984, б. 7]; бик тирән мәгънәле бер көй [Әмирхан, 1984, б. 12]; моңлы сурәт [Әмирхан, 1984, б. 13]; җазибәле кыйәфәт [Әмирхан, 1984, б. 14] һ.б.

Гадәттә, асыл һәм ясалма сыйфатлар бер үк җөмләдә кулланыла: бик матур вә килешле сурәттә тектереп [Әмирхан, 1984, б. 8]; зәңгәр күзләрдә, җазибәле кара вә мави мәгъсуманә капризлы күзләрдә [Әмирхан, 1984, б. 15]; матур гына кара тутлы бер кыз [Әмирхан, 1984, б. 22] һ.б.

Урын-вакыт кушымчалы исемнәргә *-гы* күрсәткече белән ясалган нисби сыйфатларның ешрак кабатлануы күренә: җәмгыйәттәге кешеләрнең бәгъзеләре [Әмирхан, 1984, б. 8]; уртадагы зур өстәлгә [Әмирхан, 1984,б. 9]; зурлыгындагы көндәлек гәзитәдер [б. 9], ... рояль янындагы кыз [б. 12], ... күзендәге йәшләрен [Әмирхан, 1984, б. 14] һ.б.

*-гы* кушымчасы күрсәтелмәгән очракта да нисбилек мөнәсәбәте аңлашыла: йегерме биш йәшләрендә матур гына бер йегет күренде, йегерме-йегерме ике йәшләрендә бик матур фигуралы артистка [Әмирхан, 1984, б. 12]; кырык-илле йәшендә карт [Әмирхан, 1984, б. 13] һ.б. *-гы* кушымчалы нисби сыйфатларның авторның башка хикәяләрендә дә кулланылуы күзәтелә.

Бер үк асыл-тамыр сыйфат предметның билгесен дә, процессның билгесен дә белдереп кулланыла: айакларын матур алып чабып баруы [Әмирхан, 1984, б. 20], матур сынын җитез генә турайтып [Әмирхан, 1984, б. 110] һ.б.

Ф. Әмирхан иҗатында *-лы* кушымчалы асыл-ясалма сыйфатлар, исемнәр белән янәшә кулланылып, предметның билгесен белдерәләр: йаңа фикерле шәкерте [Әмирхан, 1984, б. 33] һ.б. Фигыль белән бергә кулланылып, процессның билгесен дә белдерә алалар: ишкәкләр әллә ничек шатлыкълы йалтырыйлар, су әллә ничек шатлыкълы гына йарыла да [Әмирхан, 1984, б. 88] һ.б. Аерым җөмләләрдә сыйфат фигыль янәшәсендә булса да, сыйфатланмышына каратылганлыгы аңлашыла: үзеңез тереклекеңезгә мәгънә, тормышыңызга кызык бирә белмисез дә кызыксыз, мәгънәсез дип йылыйсыз [Әмирхан, 1984, б. 105] һ.б.

Ф. Әмирханның башка хикәя, повестьларында кулланылган сыйфатларны тикшерә бару уңаенда, һәр хикәядә уртаклыклар һәм аермалыклар булуын күрергә мөмкин. Шуңа күрә дә классик әдипләрнең әсәрләрендә файдаланыла торган тел берәмлекләрен, шул исәптән сыйфатларны тикшергәндә дә аларны һәр әсәрнең эчтәлеге белән, авторның иҗат үзенчәлеге белән бәйләп карарга кирәклек күренә.

XX гасырның беренче унъеллыгында иҗат итә башлаган Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, М. Гафури һ.б. классик әдипләрнең әсәрләрен дә аерып алып тикшерерү сорала. Өйрәнелү барышында, аеруча ике мәсьәләгә: беренчедән *олы, олуг, өлкән, зур* һ.б. сыйфатларның зат һәм предметның билгесен белдереп, икенчедән, *йахшы, тугры, туры, матур* һ.б. сыйфатларның предмет һәм процессның билгесен белдереп кулланыла алуына игътибар итү зарур, чөнки татар телендә алар ачыкланып бетмәгән дип санала [Хангилдин, 1954, б. 83–85].

*Кыскача нәтиҗәләр.* Предметның саф билгесен белдереп, асыл-тамыр, асыл-ясалма һәм фәкать ясалма рәвештә предметларның үзара мөнәсәбәтле-нисби билгеләрен белдереп, җөмләдә аергыч функциясендә кулланыла торган сыйфатлар XIX гасыр – XX гасыр башында иҗат ителгән тезмә һәм чәчмә әсәрләрдә эзлекле рәвештә кулланылышта була.

Күрсәтелгән вакыттагы әдәбиятта файдаланылган сыйфатлар, иң әүвәл, персонажларның характеры, тышкы кыяфәте, белеме, акылы һ.б. үзенчәлекләре тасвирлана торган өзекләргә нигезләнеп барланды. Әсәрдә сурәтләнә торган күпсанлы табигать күренешләренең, корылмалар, урынчалыкларның формасы, зурлыгы, күләме, төсен һ.б. якларыннан билгесен белдерә торган, шулай ук тәм һәм ис ягыннан билге белдерүче сыйфатлар, хәзерге грамматика дәреслекләрендә тәгаенләнгән төркемчәләренә туры китереп анализланды. Лексик-семантик төркем дип бүленә торган асыл сыйфатлар, морфологик бәйләнешләренә карап, лексик-грамматик төркемнәренә, ягъни асыл һәм нисби дип аерымланып, ясалышлары, вазифалары ягыннан тикшерелде. Сыйфатларның, башка сүз төркемнәренә мөнәсәбәттә, үзгә булган функцияләре барланды. Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә кулланыла торган сыйфатларны, авторның иҗат үзенчәлегенә бәйле рәвештә, мәгънәләрен күзаллау юнәлешендә анализларга туры килде.

## 5.3. Рәвеш

Лексик-семантик һәм лексик-грамматик мәгънәләре буенча, эшхәл һәм билгеләрнең сыйфатын, күләм-дәрәҗәсен, урынын, вакытын, сәбәбен-максатын белдерә алулары ягыннан, төрле төркемчәләргә бүлеп карарга мөмкин сүзләрнең, сирәгрәк предмет һәм затларның процесска бәйле булмаган билгеләрен белдерә торган гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә берләшеп, морфологик яктан формалашмаган, ягъни башка сүз төркемнәреннән аера торган формаль

күрсәткечләре булмаган, синтаксик планда, фигыльгә, рәвешкә, сыйфатка, хәбәрлек сүзгә, сирәгрәк исемгә янәшәлек юлы белән бәйләнеп, асылда, хәл, шулай ук аергыч, хәбәр функциясен үти алучы рәвеш сүз төркеменә караган сүз, сүзформа, сүзтезмәләр XIX гасырның беренче һәм икенче яртысында язылган поэзия әсәрләрендә, XIX гасырның икенче яртысыннан – XX гасыр башына кадәр иҗат ителгән чәчмә әсәрләрдә актив кулланышта була.

Л. Җәләйнең үз вакытында: «...В.Н. Хангилдин "Татар теле грамматикасы"ның һәр ике басмасында сыйфат сүз төркеменә иң тулы характеристика бирә», – дигән фикерен [Җәләй, 2000, б. 64] рәвеш сүз төркеменә карата да әйтергә мөмкин. Автор күпсанлы мисаллар белән рәвеш сүз төркемен төрле яклап тикшереп, түбәндәге нәтиҗәгә килә: «Татар телендә рәвешнең лексик һәм грамматик чикләрен ачыклау мәсьәләсе шактый катлаулы, чөнки рәвеш үзенең лексик-семантик эчтәлеге һәм грамматик төзелеше буенча бик күп төрлелекне эченә ала. ... Ләкин аларның берсе дә, кайбер телчеләр уйлаганча, татар телендәге рәвеш төркемен грамматикадан сызып ташлар өчен нигез була алмыйлар. Татар телендә рәвеш сүзләр күптән булган һәм алар өзлексез арта, күбәя баралар» [Хангилдин, 1954, б. 272]. Рәвеш сүзләрнең ничек итеп арта, күбәя баруы иске татар телендә язылган текстларны тикшерә бару уңаенда күренергә тиеш иде, әмма бу мәсьәлә ныклы системага салынып өйрәнелгән дип әйтеп булмый. Иске татар телендә язылган истәлекләрне тикшерүчеләрдән, Я.С. Әхмәтгалиева [Ахметгалеева, 1979, с. 101–102], Ә.Р. Исхакова [Исхакова, 2005, с. 156–161], А.Ф. Йосыпов [Юсупов, 2006, с. 76–80], Р.Ф. Мирхәев [Мирхәев, 2007, б. 56–61], Г.Ф. Гайнуллина [Гайнуллина, 2010, б. 91–98] һ.б. өйрәнелә торган әсәрләрендә кулланылган рәвешләрне җентекләп анализлыйлар.

XIX гасыр – XX гасыр башында иҗат ителгән әсәрләрдә рәвеш сүз төркеменә караган сүзләрне тикшерү, хәзерге татар әдәби телендә өйрәнелә торган тәртиптә барды [Татар грамматикасы, 2002, б. 65–71; Хисамова, 2006, б. 282–291]. Тезмә һәм чәчмә әсәрләр аерым тикшерелде.

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви-әл-Сәгыйди» әсәрендә (1845, 1889) билге рәвешләренең түбәндәге төркемчәләре файдаланыла:

а) эш-хәлнең ничек үтәлүен һәм аның дәрәҗәсен белдерүче рәвешләр: дөзетер филхәл [Каргалый, 1889, б. 3]; кидәр андан фәрехшад [Каргалый, 1889, б. 3]; дөнйадин кичер безе сағ-у-сәлим [Кар-

галый, 1889, б. 4]; утырдылар бәһәм [Каргалый, 1889, б. 4]; аныңла бағлады мөхкәм биғайәт [Каргалый, 1889, б. 7] һ.б.

ә) эш-хәлне күләм-чама ягыннан ачыклый һәм микъдарын белдерә торган рәвешләр: күп улыр, отыры улачақ билә гыйтаб [Каргалый,1889, б. 3]; тәүбә итәсез сәрбәсәр [Каргалый, 1889, б. 9]; шәйәрү әтрафын қошадыб сәрбәсәр [Каргалый, 1889, б. 10] һ.б.

б) эш-хәлне чагыштыру аша ачыклый торган (охшату-чагыштыру) рәвешләр: Хөббе дөнйа уламы мондыйун зийад, ... мондыйун отры улачақ билә ғыйтаб [Каргалый, 1889, б. 3],

Мисаллардан күренгәнчә, рәвешнең барлык төркемчәләрендә дә төрки-татар һәм гарәп-фарсы алынмаларының, асылда, бер дәрәҗәдә файдаланылуы күренә. Алынмалардан чыганак телләрендә рәвеш булганнарының да, үз телләрендә рәвеш булмаганнарының да (ягъни башка сүз төркемнәренең) төрле синтаксик бәйләнештә эш-хәлнең үтәлү рәвешен белдерү функциясендә кулланылуы күзәтелә. Текстлардагы рәвешләрне ясалышлары ягыннан тамыр, парлы, кушма, тезмә формаларга бүлеп карарга мөмкин.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыл адәб» хезмәтендә (1856, 1900) түбәндәге рәвешләрнең кулланылуы күзәтелә:

а) эш-хәлнең ничек үтәлүен белдерә торган билге рәвешләре: Иғанәт эстәрем исмеңә Алла, сәнам улдыр сәңә әлхамделиллә, сәнең исемең телемдә вирдәм улсун, дәхи хәббең күңелдә дәрдәм улсун [Салихов, 1856, б. 2] һ.б.

ә) эш-хәлне күләм-чама ягыннан ачыклый торган рәвешләр: һаман үз мақсатына йылдырырлар [Татар әдәбияты, 1957, б. 60] һ.б.

б) эш-хәлнең үтәлү вакытын белдерә торган рәвешләр: андыйун сән торырсың, ...чықсам бу дәм [Татар әдәбияты, 1957, б. 54] һ.б.

в) эш-хәлнең үтәлү урынын белдерә торган рәвешләр: ...килә йөрер йақында бер йыланы, ... йылан ул дәм якыйун кәлде, җитеште [Татар әдәбияты, 1957, б. 54] һ.б. Аңлашылганча, бу авторның әсәрендә дә рәвешләрнең барлык төркемчәләренең кулланылуы күзәтелә.

Г. Кандалыйның шигырь һәм поэмаларында, традиция буларак, барлык сүз төркемнәренең дә, гарәп һәм фарсы алынмалары дәвам иткән хәлдә, хәзерге татар телендә актив кулланылышта булганнары ешрак кабатлана. Бу үзенчәлек рәвеш сүз төркемендә дә чагылыш таба. Шуңа күрә аларны хәзерге татар телендәге кебек, лексик-семантик төркемчәләре һәм лексик-грамматик формалары ягыннан жен-

текләбрәк өйрәнергә мөмкин. Аларның барысы да гашыйк кешенең эше-хәле ни дәрәҗәдә булуын сурәтләргә ярдәм итә.

1. Г. Кандалый әсәрләрендә билге рәвешләренең түбәндәге төрләре кулланыла:

а) эш-хәлнең ничек үтәлүен һәм аның дәрәҗәсен белдерә торган рәвешләр: йаза алмай турыдан [Кандалый, 1988, б. 73]; нигә тиз мине йатсындың [Кандалый, 1988, б. 75]; җәйәү йөреп сыйрак талды [Кандалый, 1988, б. 75]; лап-лоп итеп басып [Кандалый, 1988, б. 83]; ашық-пошық намаз қылғач [Кандалый, 1988, б. 98] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, бу төр рәвешләр тамыр, ясалма, кушма хәлдә файдаланыла. Алар саф билге төшенчәсен белдерүләре ягыннан асыл сыйфатларга якынаялар. Аерым асыл сыйфатлар процессны белдерә торган сүз белән янәшә кулланылганда, эшнең үтәлү рәвешен (хәлен) белдерә торган вазифа үтиләр. Бу очракта *яхшы* сыйфатының әлеге мәгънәдә еш кабатлануы күзәтелә: тутыр бик йахшы қорсақны [Кандалый, 1988, б. 97]; йахшы аңла, йахшы аңлап торың имди [Кандалый, 1988, б. 113] һ.б.

ә) күләм-чама, сан, микъдар рәвешләре: ғомерләр үтте күп бушқа [Кандалый, 1988, б. 74]; күп ашап саташып [Кандалый, 1988, б. 98]; тоташ йанды йөрәгем, сәне сәүдем бинияайә хәддин ашып [Кандалый, 1988, б. 131]; йазамын күп [Кандалый, 1988, б. 150]; күп уқыдым хәдисдин [Кандалый, 1988, б. 207]; бер аз монча ғаҗәб сүз әйделенде [Кандалый, 1988, б. 216] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, бу төргә карый торган *күп* рәвеше, эш-хәлнең билгесен дә, предметның билгесен дә белдереп файдаланыла: йазамын күп ... бу күп сүз эчрә, ... күп хәсрәтләр күрер өчен һ.б. Тезмә хәбәр буларак файдаланыла: җиһанда қыз күп улыр [Кандалый, 1988, б. 218] һ.б.

б) охшату-чагыштыру рәвешләре саф билгене чагыштырмача тәгъбир итәләр, ясалма һәм фразеологик төрләрдә генә булалар [Хангилдин, 1954, б. 294]. Г. Кандалый иҗатында бу төр рәвешләр дә хискичерешләрне һәм чибәрлекне тасвир итү чарасы буларак файдаланыла: бағ алмадай пешеп тулсам [Кандалый, 1988, б. 77]; Чығамын дәхи сахраға, Йөрәгем утдай йанғанға [Кандалый, 1988, б. 91]; Сәне белгән идем туғры үземдик / Сүзеңә дә инандым үз сүземдик [Кандалый, 1988, б. 165] һ.б.

2. Хәл рәвешләренең Г. Кандалый әсәрләрендә түбәндәге төрләре файдаланыла:

а) урын рәвешләре: туған илем йырақ қалды [Кандалый, 1988, б. 75]; мәхәббәтсез кешедән бик йырақ қач [Кандалый, 1988, б. 95]; күземдән йырақ булдың [Кандалый, 1988, б. 215] һ.б.

В.Н. Хангилдин үз вакытында: «*югары, түбән, якын, ерак, аз, күп* кебек сүзләр рәвешкә күчү процессын кичерәләр», дигән искәрмә ясый [1954, б. 275]. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ерак, якын* сүзләре рәвеш дип билгеләнә, сыйфат мәгънәсендә кулланылуы искәртелә [Татар теленең…, 1977, б. 332].

ә) вакыт рәвешләре: даим мәдрәсәдә тордым, җаһиллегем бүген белдем, һаман тордым үзем қышда [Кандалый, 1988, б. 74], һәмишә күңеле сынықдыр [Кандалый, 1988, б. 86]; бүген без утырдық хушлап [Кандалый, 1988, б. 100]; озақ бергә торалмадым [Кандалый, 1988, б. 91]; яна кич-төнләре буйлый [Кандалый, 1988, б. 117] һ.б.

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, XIX гасырның беренче яртысында иҗат ителә торган поэзия әсәрләрендә төрки телнең а) абруйлы төрки һәм ә) халыкчан төрки дип бүленгән ике төрдә язылуы, Г. Кандалый иҗатында аларның икесенең бергә кушылып файдаланылуы аңлашыла.

XIX гасырның икенче яртысында Г. Чокрый һәм М. Акмулла иҗатының да, асылда, шул юнәлештә баруы, ягъни гарәп-фарсы алынмаларының файдаланылуы дәвам ителгән хәлдә, татар халкының җанлы-сөйләмә һәм авыз иҗаты әсәрләренә хас булган сүз, сүзформа, сүзтезмәләренең эзлекле кулланылуы күзәтелә.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә:

а) эш-хәлнең ничек үтәлүен һәм дәрәҗәсен белдерә торган билге рәвешләре: ақырын җәйәүләтеп артқа төштек [Акмулла, 1892, б. 4]; иясе қадәри хәл гамил булса [Акмулла, 1892, б. 5]; тиз керсә йарар иде оҗмахқа шул [Акмулла, 1892, б. 6] һ.б.;

ә) эш-хәлне күләм-чама ягыннан ачыклый торган рәвешләр: күп сөйләнмә [Акмулла, 1892, б. 31]; тәҗавез қылдыңыз күп [Акмулла, 1892, б. 35]; кешене танымай күп бәйләнсәң [Акмулла, 1892, б. 41] һ.б.

б) эш-хәлне, процессны чагыштыру аша ачыклый торган рәвешләр, *-дай/-дәй* кушымчалы охшату-чагыштыру рәвешләре эзлекле рәвештә тезелеп кулланыла, әсәрнең ритмын-көен барлыкка китерә: Болағы – саф, чәйгә һәркем су алғандай, ... чуллағанлар қуанғандай, ... су алғандай, ... адәм қуанғандай,... қалды җуалғандай, ... имәс чубалғандай, ... инанғандай [Акмулла, 2001, б. 10]; Қай эше ул фазыйл-

ның таң қалмастай, ... күз салмастай, ... сызланмастай, алданмастай, ... җан қалмастай [Акмулла, 1892, б. 11–12] һ.б. Бу төр рәвешләр тезелмичә дә бирелә: ишеткән адәмләрне йылатқандай [Акмулла, 1892, б. 5] һ.б. Шул ук кушымчаның исемнәргә кушылып ясалган рәвешләрдә кулланылуы да күзәтелә: Ул заман китап кайда бу замандай [Акмулла, 1892, б. 12]; ...төлкедәй йөгрекмен дип ашсаңыз да [Акмулла, 1892, б. 6]; чаяндай чыдай алмай чагарсыз сез [Акмулла, 1892, б. 7] һ.б.

*-ча/-чә* кушымчалы чагыштыру рәвешләренең дә файдаланылуы күзәтелә: Сүзенә мин артықча ғашыйқ аның [Акмулла, 1892, б. 11]; Қазақча шиғырь йаздым ачық қылып [Акмулла, 1892, б. 9]; ...морадынча йитәкләп алып йөреп [Акмулла, 1892, б. 31] һ.б.

*Күп* рәвеше, зат яисә предмет атамасын ачыклап, аергыч вазифасында кулланыла: Күп ғалимләр, мөдәррисләр аннан чықған, ... күп ғалим ул ғазизгә қырын булган [Акмулла, 1892, б. 10], ... күп қайғы тарта-тарта без исергән [Акмулла, 1892, б. 32]; ...күп сәлам [Акмулла, 1892, б. 36] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, М. Акмулла иҗатында рәвешләрне куллануда традиция дәвам ителгән хәлдә, аның үзенә генә хас булган тасвирлау алымы да ачык күренә.

Г. Тукайның башлангыч чор иҗатында, язма традиция дәвам ителеп, гарәп-фарсы алынмалары да, шул ук вакытта, сөйләмә телдәге рәвешләр дә иркен кулланыла. Боларның кабатлану ешлыгы «Г. Тукай. Шигърият теле. Сүзлек» хезмәтендә төгәл күрсәтелә. Билге рәвешләреннән, эш-хәлнең ничек үтәлүен һәм аның дәрәҗәсен белдерә торган *тиз* рәвеше – 51, *тиздән* – 4, *тиз-тиз* – 13, *тизүк* – 6 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, б. 186–188]: Син тиз барырсың судлара [Тукай, 1985, б. 79]; Ашар безне дә бу қорсақ, басар тиз [Тукай, 1985, б. 92]; мин һәм тиздән менәм дарға [Тукай, 1985, б. 164]; тизүк уйныйқчы бераз [Тукай, 1985, б. 170]; Уқыйм тиз-тиз күңелдән бер ғаҗаиб сүрә Қоръәннән [Тукай, 1985, б. 208] һ.б.

Шул ук мәгънәдә *бәнагяһ* һәм *кинәт* рәвешләре берәр мәртәбә файдаланыла: бән бәнагяһ тәwәққыф әйләдем һәм улдым агяһ [Тукай, 1985, б. 51]; Кинәт кенә җиккән атың туқтап кала [Тукай, 1985, 2, б. 262].

9 мәртәбә кулланыла торган *туры* сүзе 6 мәртәбә рәвеш вазифасын үтәп файдаланыла: Бу бабай фикрен туры итсен Хода [Тукай, 1985, б. 264] һ.б. *Туп-туры* рәвеше 5 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, б. 215]: Җиктереп пар ат, Қазанға туп-туры киттем қарап [Тукай, 2009, б. 158] һ.б. 25 мәртәбә кабатлана торган *тугъры* сүзе 6 мәртәбә рәвеш вазифасында кулланыла: Китсен туғры, ғыйрфан җәсирәсен қарап

[Тукай, 1985, б. 201]; Төтеннәр туғры чықса [Тукай, 1985, б. 309]; туғры килде бер суға [Тукай, 1985, б. 229] һ.б. Аңлашылганча, Г. Тукай шигырьләрендә *туры* һәм *тугъры* сүзләренең мәгънәләре, асылда, җитәрлек дәрәҗәдә аерымланып кулланыла дияргә мөмкин.

Эш-хәлнең ничек үтәлешен белдерә һәм төрле ысул белән ясала торган кушма рәвешләрнең дә еш кабатлануы күзәтелә: ...дер-дер қалтырыйдыр [Тукай, 1985, б. 51]; шылтыр-шылтыр йулдин арбалар китәдер [Тукай, 1985, б. 55]; бозлар аға тау-тау булып [Тукай, 1985, б. 55]; оча турғай да пыр-пыр [Тукай, 1985, б. 110]; җилбер-җилбер җил бәрсә дә [Тукай, 1985, б. 130]; туп-туры киттем қарап [Тукай, 1985, б. 158]; йалт-йолт киләдер эчкә батқан күзләре [Тукай, 1985, б. 170 һ.б.

Эш-хәлне күләм-чама, микъдар ягыннан ачыклый торган *аз* рәвеше Г. Тукайның шигърият телендә 22 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 35]: Аз ғына сабыр ит әле, Ғадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле [Тукай, 1985, б. 169], Аз ғына мәғрурланып тордым буғай [Тукай, 1985, б. 277] һ.б.

*Бераз* кушма рәвеше 21 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, б. 157]: Сезгә даир бераз йаздым, кәләнчә иқтидарымнан [Тукай, 1985, б. 84]; ул тик бераз үссен дә ир булсын [Тукай, 1985, б. 155]; Гәрчә анда туғмасам да мин бераз торған идем [Тукай, 1985, б. 168] һ.б.

*Күп* рәвеше 140 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, б. 476–479]: Чиновниклар безнең қанны бик күп имде [Тукай, 1985, б. 42], Күп тә йаздым, кариэм, сез ардығыз [Тукай, 1985, б. 76]; күп ашап йоткач [Тукай, 1985, б. 116] һ.б. Ул турыдан-туры фигыль белән бәйләнмәгән очракта да, рәвешлеген саклый: җыйғач күп запас [Тукай, 1985, б. 32]; Күп йәш йегетләр үлде [Тукай, 1985, б. 40]; Булсын күп-күп сәламнәр [Тукай, 1985, б. 41] һ.б.

Эш-хәлне, процессны чагыштыру аша ачыклый торган рәвешләр:

а) *-ча/-чә* кушымчалы чагыштыру рәвешләре: Син үзеңне безнеңчә йөрт, безнеңчә тот [Тукай, 1985, б. 222]; Қуркыныч бит қышны сезчә қышласаң [Тукай, 1985, б. 254] һ.б.

ә) *-дай/-дәй* кушымчалы чагыштыру рәвешләре: Мәхәл вармы борынғыдай хәзән, хәсрәт, әләмләргә [Тукай, 1985, б. 25]; Синең өй балчықтан, Бөкрәйгән қарчықтай [Тукай, 1985, б. 32]; Эреп йокласам мин сары майдай [Тукай, 1985, б. 111]; Қузғалып китте вагон, җилдәй бара [Тукай, 1985, б. 267] һ.б.

б) *-лап/-ләп* кушымчалы рәвешләр: Нурлы йолдызлар берәмләп сүнделәр [Тукай, 1985, 2, б. 177]; Сөйләшик бергәләп [Тукай, 1985, 2, б. 81] һ.б.

Хәл рәвешләреннән:

а) урын рәвешләре: Йырақ анлар қалдыйа [Тукай, 1985, б. 40], йақын бармыйқ [Тукай, 1985, б. 109]; Ары барып, бире килеп, бер дә файда тапмағач [Тукай, 1985, б. 116] һ.б.

ә) вакыт рәвешләре: Сезсеңез милләт йулында даимән қаим улан [Тукай, 1985, б. 84], Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә ғаид, милләтем [Тукай, 1985, б. 114]; Бәғзан пешкән дип уйласам да чи чыға [Тукай, 1985, б. 176] һ.б.

Сәнгатьле прозаның автор сөйләме булып хикәяләнә торган беренче әсәрләрендә рәвеш сүз төркеменең кулланылыш үзенчәлеген күз алдына китерү өчен, К. Насыйриның сәнгатьле чәчмә әсәрләренә мөрәҗәгать итәбез, хәзерге татар телендә кабул ителгән тәртип нигезендә тикшерәбез.

Билге рәвешләреннән:

а) эшнең үтәлү рәвешен белдерә торган рәвешләр:

«Кырык вәзир»дә: тиз хәбәр қалдырдылар [Насыйри, 1975, б. 225]; саф-саф итеп ... қуй [Насыйри, 1975, б. 226]; тиз-тиз ишеккә килеп [Насыйри, 1975, б. 229]; терелэй тиресен тунап [Насыйри, 1975, б. 235]; туры сөйлим [Насыйри, 1975, б. 241]; мин сине бик иләсмиләс күрдем [Насыйри, 1974, б. 242] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: иттифақан ул заманда ике җаду пәйда булып [Насыйри, 1974, б. 213]; зар вә гирйан булды [Насыйри, 1974, б. 214]; гөруһ-гөруһ килеп [Насыйри, 1974, б. 215]; безләрне хәйран вә ғақылымызны пәришан қылды [Насыйри, 1974, б. 216]; тиз йөрерләр [Насыйри, 1974, б. 217] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, үзләре бәйләнгән фигыльдән аңлашылган эш яки билгенең сыйфатын белдерү вазифасын үти торган рәвешләрнең күбесенең кушма хәлдә (тиз-тиз, сөртә-сөртә, сөрә-сөрә һ.б.), ясалма (терелэй, бахозур һ.б.] һәм төп (тиз, туры һ.б.) халәттә файдаланылуы аңлашыла.

ә) эш-хәлне күләм-чама ягыннан ачыклый торган рәвешләр:

«Кырык вәзир»дә: бирсәң аз бир [Насыйри, 1975, б. 225]; җәлләдне суғыш көнендә ғаскәр күп табылыр [Насыйри, 1975, б. 226]; баштанайак уғрыга сөйләде [Насыйри, 1975, б. 229] бераз барғач күрде [Насыйри, 1975, б. 238] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: түшәме азрақ иңгәнме, идәне бераз күтәрелгәнме [Насыйри, 1974, б. 209]; майы тәмам сеңеп беткәч [Насыйри, 1974, б. 212]; wақыт аз калды [Насыйри, 1974, б. 228] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, бу рәвешләрнең кайберләренең (күп адәм табармын, бераз адәм хәзерләп бир [Насыйри, 1975, б. 226], күп доға қылдым [Насыйри, 1975, б. 232], күп ғыйлем хасыйл итеп [Насыйри, 1974, б. 209]) мисалларындагы рәвешләр предмет белән янәшә кулланылып, аның билгесен белдерү функциясен башкарулар [Хангилдин, 1954, б. 275].

б) охшату-чагыштыру рәвешләре саф билгене чагыштырмача тәгъбир итәләр:

«Әбүгалисина кыйссасы» нда: бу тариқча (ысулча) ничә йыллар ғыйлем хасыйл итеп... [Насыйри, 1974, б. 209]; ахыр шул кәйфийәтчә қычқырышып диwанға барып җиттеләр [Насыйри, 1974, б. 253] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, бу рәвешләр ясалма һәм фразеологик төрләрдә генә булалар.

Хәл рәвешләреннән:

а) урын рәвешләре:

«Кырык вәзир»дә: йырақ торды [Насыйри, 1975, б. 235] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: йуғары чығып утырдылар [Насыйри, 1975, б. 221] һ.б.

ә) вакыт рәвешләре:

«Кырык вәзир»дә: беркөн анасы... wафат булды [Насыйри, 1975, б. 222]; көннән-көн уғланның җәмалын күргән сайын, һаман... кичәкөндез хәйлә белән мәшғүл булды [Насыйри, 1975, б. 222]; иртәгә аны чақыртып [Насыйри, 1975, б. 234] һ.б.;

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: өйләгәчә дәрес уқыр [Насыйри, 1974, б. 209]; һаман чыкмаган иде [Насыйри, 1974, б. 209]; иртәгә хәзер булсын [Насыйри, 1974, б. 210] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, үзләре бәйләнгән фигыльдән аңлашылган эшнең вакытын белдерә торган вакыт рәвешләренең һәр ике кыйссада да эзлекле кулланылуы күзәтелә.

Сәнгатьле прозаның автор сөйләме булып хикәяләнә торган икенче төрен башлаган М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында рәвешләрнең барлык төркемчәләре дә кулланыла.

1) Билге рәвешләреннән:

а) эшнең үтәлү рәвешен белдерә торган рәвешләр: турыдан-туры сүрә уқытыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; уфақ-уфақ атлап

кәчән wақытта, ... челдер-челдер орылыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50], шпалеры йуаш-йуаш йармаға башлады [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51]; ...киртек-миртек җаwапланмаз иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51]; сезә тиз вирерләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53] һ.б.;

ә) эшне-хәлне күләм-чама ягыннан ачыклый торган рәвешләр: ...пәк мөшкел иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 49]; менланың күзенә тәмамән күренде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50]; чуқ бакмыйдыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51]; чуқ тәэсир итде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 57] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, *чуқ* рәвеше һәм аергыч функциясендә, һәм хәл вазифасында кулланыла. Аерым очракларда ул *күп* синонимы белән чиратлаша.

«Татар теле морфологиясе» дәреслегендә, башка хезмәтләрдә күләм-чама рәвешләре дип бирелгән сүзләр, эш-хәлнең үтәлү дәрәҗәсен яки билгенең дәрәҗәсен белдерә торган дип, аерылып күрсәтелә [Хисамова, 2007, б. 283]. *Дәһа* рәвеше менә шушы бүлемгә туры килә булса кирәк: мораты дәһа артты [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 58] һ.б. Шунда ук пәк, ғайәт, тәмаман һ.б. рәвешләрне дә карарга мөмкин: пәк килешә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 62]; ғайәт шат улды [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 66]; йәш кыз тәмамән йегетнең ихтыйарына вирелде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 69] һ.б.;

б) охшату-чагыштыру рәвешләре саф билгене чагыштырмача тәгъбир итәләр: ислам шәриғәтенчә торсалар иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 60] һ.б.

2) Хәл рәвешләреннән:

а) урын рәвешләре: Идел нәһерендән озак дәгел, бер татар аwылы мәүҗүддер, ... урта җамиғдан йырақ дәгел бер кечек ханә вар [Акъегет, 1886, б. 2]; ...йәш қыз тротуар үзәрә иләрү җөрде [Акъегет, 1886, б. 57]; бән буны йырақ гизләрмен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 62] һ.б.

Бу әсәр иске татар теленең яңа җәдиди варианты («Тәрҗеман» теле) үзенчәлекләре мул куллаланылганга, аерым рәвешләр угыз-төрек телендәгечә файдаланыла, яисә сүзнең мәгънәсе үзгәрә, мәсәлән, *озақ* сүзе хәзерге татар телендә урын рәвеше түгел, күләм-чама рәвеше, *йарын* сүзе татарда икенче ел, төрекләрдә икенче көн буларак кулланыла, ягъни лексик-семантик вариантлылык хасил була.

ә) вакыт рәвешләре: ғади ханәләр кеби ағачдан вә башлары бәғзән саламнан, бәғзән ағачдан йасалмышдыр [Акъегет, 1886, б. 3]; ...һаман қычқырмақда иделәр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 56]; ...вә йортда қапу алдында вә бәғзән урамда Хәнифә илә раст килмәгә чалышыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 57]; шимди исә бер күрмәклә қәнәғәтләнмәйеп мораты дәһа артты [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 58]; бүген-иртәгә эшне тәмам итәчәкләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 69]; ...бән сәне әүwәл әдәп өчен йахшылық илә сорармын [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 69]; ...шимди ... эстәйүрләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 72] һ.б.

Рәвешләрнең башка функция үтәп файдаланылуы турында әйтелә барды. Бу мәсьәләгә нәтиҗә ясап, болай дип әйтергә мөмкин: *чуқ, күп* рәвешләренең эзлекле булып, предметның билгесен белдереп кулланылулары күзәтелгәнгә күрә, әлеге текстта бу сүзне тулысынча рәвешкә күчеп беткән дип әйтә алмыйбыз.

Шуның белән аерым сыйфатларның, мәсәлән, *зийадә, туғры, йахшы, йаман* һ.б. сүзләрнең үз вазифаларын үтәгәннәре хәлдә, процесс билгесен дә белдереп, хәл функциясендә файдаланылуы күренә: сән бәни янә зийадә сәвәчәксең [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 69]; ...қапуйа туғры варыб [Акъегет, 1886, б. 4]; ...йахшы белер иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48, 52,]; бәхәсләреңи йахшы хәзер әйлә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында, рәвешнең барлык лексик-семантик төркемнәре файдаланыла. Аларны гарәп вә фарсы алынмалары дип, угыз-төрек һәм, әлбәттә, күбесен татар теленә мөнәсәбәтле рәвештә бүлеп карарага мөмкин. Тамыр рәвешләргә караганда, төрле ысуллар белән ясалган, бигрәк тә, сөйләмә телдә актив булган кушма рәвешләрнең күбрәк булуы күренә.

З. Бигиев, Ф. Кәрими һәм Р. Фәхретдин кебек мәгърифәтчеләрнең әсәрләрендә, угыз-төрек теленә мөнәсәбәтле рәвешләрне, хезмәтенең темасына туры китереп, Р.Ф. Мирхәев анализлый [Мирхаев, 2007, с. 56–61]. Бу әдипләрнең әсәрләрен үз вакыты әдәби теленең өч варианты белән язулары мәгълүм. Менә шушы аермалылык, рәвешләрнең кулланылышында ничек итеп чагылуын билгеләү өчен, аларның иҗатын алга таба җентекләп тикшерергә кирәк булачак. Беренче җөмләләрен укый башлагач та, З. Бигиевнең романнарына караганда, «Мавәраэннәһердә сәяхәт» («Транс-Оксанияйә сәфәр») әсәрендә

(1908), башка сүз төркемнәре кебек үк, рәвешләрнең дә гарәп-фарсы алынмалары булганнарының эзлеклерәк кулланылуы күзәтелә: ...бән дә әхйанән вабурның өстге сәтыхына чыгып, ... әхъянән ғамиқ әфкярләрә талып [Бигиев, 1991, б. 289], ... ул тарафда дин қарендәшләремезнең шимдеки хәлләрене әүвәлге хәлләренә қыйас идеп [Бигиев, 1991, б. 290] һ.б.

Шундый ук хәл, Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә күренә, ягъни хикәяләренә караганда алынма рәвешләр күбрәк кулланыла. «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә: ...бу хәзерлекләр китәчәге йулың вә гизәчәге wақытың озынлығына нәзарән ижра иделмешдер [Кәрими, 1902, б. 2]; ...сәйәхең күз ишарәтенә мөнтәзыйр торайурлар, ... Шакир әфәнденең қордығы планы мөҗибенчә, ... болардан мағада [Кәрими, 1996, б. 151]; ...бу йирләре биззат китеп күрмәк [Кәрими, 1902, б. 5]; ...эксәрийән кәнделәренә шөйлә русча исем вирәләр [Кәрими, 1996, б. 155] һ.б. Бу үзенчәлек Р. Фәхретдиннең, сәнгатьле чәчмә әсәрләренә караганда, «Асәр» җыентыгында (1900–1909) чагылыш таба.

Шуның белән бергә, әлеге авторларның сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә дә процессның яисә билгенең билгесен белдерә торган халыкчан рәвешләрнең яратып кулланылуы күзәтелә. Ф. Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә (1897) эшнең үтәлү рәвешен белдерүчеләр: йәш wақытлар инсанның күңеленнән тиз китмәйдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 221], бик тәфсилләп аңлатмага башлады [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 222], йалынып-йалwарып бераз баштанрақ сөйләтмәгә башлыйбыз [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 222]; ...берwақыт үзеннән шул рәвешчә сорадым, боларны әүвәлән ул биргәндә генә истигъмал итсәм дә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, 222] һ.б. «Шәкерт илә студент» әсәрендә (1899): әйдә тизрәк керик, тәмам өстенә басты [Кәрими, 1996, б. 31], пароход ақрын-ақрын қузғалып пристаньнан айырылды, ... туп-туғры барып, кисәктән хәтеремә бер фикер килде [Кәрими, 1996, б. 32] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1898) әсәрендә билге рәвешләренең түбәндәге төркемчәләре файдаланыла:

а) эшне-хәлне күләм-чама ягыннан ачыклый торган рәвешләр: чуқ шөкерләр улсын [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 264, 267] һ.б. Бу төркемчәдәге кайбер рәвешләр, исемнәр белән янәшә кулланылып, аларны күләме ягыннан ачыклап киләләр: бу кеби вәгәзләрне әйтмәк күп ирләр йәки күп мөдәррисләргә һәм насиб улмаз [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267] һ.б.

ә) охшату-чагыштыру рәвешләре саф билгене чагыштырмача тәгъбир итәләр: ...тәхсилең артдықча кечелегең, белекең артдықча сабырың артсын [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267] һ.б.

Хәл рәвешләреннән:

а) урын рәвешләре: шуның өчен сәне йырақ, йәғни Қазан шәһәренә йебәрәмен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267] һ.б.;

ә) вакыт рәвешләре: ибтидаән Уфаға барачақ идем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 269] һ.б.

Классик әдипләрнең башлангыч чор иҗатында рәвеш сүз төркеменә караган сүзләрнең кулланылышында, алдагы чорлардан килә торган традиция дәвам итеlә, шуның белән бергә, һәр яктан халык сөйләменә якынаю бара. Г. Исхакыйның «Тәгәллемдә сәгадәт...» (1899) хикәясендә билге рәвешләреннән:

а) эшнең үтәлү рәвешен белдерүчеләр: тизрәк өйгә кайтыйм, тизрәк барып җитәргә кирәк [Исхакый, 1998, б. 38]; йалтыр-йолтыр әйләндерәләр [Исхакый, 1998, б. 41], рәхәт-рәхәт ғомерләрен уздырырлар [Исхакый, 1998, 49] һ.б.

ә) эшне-хәлне күләм-чама ягыннан ачыклый торган рәвешләр: ...синнән күп өйрәнерләр [Исхакый, 1998, б. 32]; шәкертләренең күп белүләренә [Исхакый, 1998, б. 34]; бу арада аның эше бик күп [Исхакый, 1998, б. 40] һ.б.

б) эш-хәлнең үтәлү дәрәҗәсен яки билгенең дәрәҗәсен белдерә торган рәвешләр: ...бик җибәрергә телим дә, үзенең дә бик барасы килә [Исхакый, 1998, б. 33]; бөтенләй дә уқытыр идем [Исхакый, 1998, б. 35]; бөтенләй түләп керергә җитә [Исхакый, 1998, б. 36] һ.б.

Эш-хәлнең үтәлү вакытын белдерә торган хәл рәвешләре: берwақыт шәкерт булган, ... һәрwақыт шөкранәдә булырға кирәк [Исхакый, 1998, б. 32]; ...бүген мәчеттә [Исхакый, 1998, б. 33]; ...былтыр қалаға барғанда [Исхакый, 1998, б. 34]; бу йыл ... кийәрмен [Исхакый, 1998, б. 37]; иртәгә китәрмен [Исхакый, 1998, б. 38]; ...бүген җомға көн инде, бүген китмә [Исхакый, 1998, б. 41]; ...иртәгә ғомуми дәрес башланачағын сөйләделәр, ... безнең өчен һәрwақыт хәйер-доғада булығыз, ... һәрwақыт шөкранәдә булыр [Исхакый, 1998, б. 42] һ.б. Г. Исхакыйның башка әсәрләрендә дә рәвешләрнең шундый ук тәртиптә кулланылуы күзәтелә.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) хикәясендә эш яки билгене сыйфатлау хезмәтен үтәүче билге рәвешләреннән:

а) эшнең үтәлү рәвешен белдерә торган рәвешләр: җилбер-җилбер селкенешеп утырған ағач йафраклары [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 399]; ...эре-эре идеп шәмаил йаза [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 401]; ...тирләп-пешеп қуып йөргәндә [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 406]; ...дөбер-шатыр чығып киттеләр, ... шақыр-шоқыр туңып [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 408] һ.б.

ә) эшне-хәлне күләм-чама ягыннан ачыклый торган рәвешләр: ...шәкерт күп җыйылғанча [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 399]; ...азрақ йоқлады да иртә торып, ... азрақ ачылды [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 405] һ.б.

б) эш-хәлнең үтәлү дәрәҗәсен яисә билгенең дәрәҗәсен белдерә торган рәвешләр: ...шәкертләр хақында улан хыйалы бигрәк нықланды [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 400]; ...ғәпләре бик килеште, ... бик шатланды [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 402]; ...тәмам өйрәнеп җиткәнгәчә, ... бик мәсхәрәләделәр [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 406]; ...бик мөшкилләнде [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 407] һ.б.

Эш-хәлнең үтәлү вакытын белдерә торган хәл рәвешләре: моңарча анасыннан һич айырылмаған ... озақ та үтмәде [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 400]; ...бик озақ сөйләшеп утырып [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 401]; ...хәзердән бер өмидсезлеккә төште [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 400]; кичә дә мысқыл иткәннәр иде, бүген дә берәр эш қылмасалар йарар иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1974, б. 405] һ.б.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» (1907) хикәясендә: ...мин хикәяне бик аз төзәттем [Әмирхан, 1984, б. 7]; ...бу кеше диңгезе даим бер хәрәкәттә тора иде, ... күзләрен мөлайемәнә йасап йаныма киләләр [Әмирхан, 1984, б. 8]; ...қыз аwыр ғына сурәттә татарча мохатәбә қыла, студент та аның белән русча сөйләшә, ... бик диққәтләп әллә нәрсә уйнап утыралар [Әмирхан, 1984, б. 9]; ...қайчы белән кисеп төшергән кебек, бердән туқтады [Әмирхан, 1984, б. 12]; ...халық күп җыйылган, ... тиз генә чығар өчен [Әмирхан, 1984, б. 15].

*Кыскача нәтиҗә.* Тикшеренүләрдән күренгәнчә, рәвешләрнең барлык төркемчәләрен куллануда, традиция дәвам иткән хәлдә, сөйләмә телгә хас формаларның әдәбиләштерелүе, ягъни хәзерге әдәби тел нормасында ныгуы күзәтелә.

## 5.4. Сан

Мәгънәсе буенча, бер төрдәге предметларның данә исәбен, сан ягыннан микъдарын белдереп, үзенә генә хас булган *-ынчы/-енче (-нчы/-нче); -ау/-әү, -ар/-әр/-шар/-шәр; -лап/-ләп* форма ясагыч күрсәткечләре белән, гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә, лексик-грамматик яктан гомумиләшеп, микъдар саны (төп сан), тәртип, җыю, бүлем, чама саны дигән төркемчәләргә берләшеп, саналмышы берлек санда әйтелә, исем белән аергыч һәм аерылмыш мөнәсәбәтендә, фигыль белән бәйләнештә хәл функциясендә килә торган сүзләрнең *сан* сүз төркеме дип аталуы мәгълүм.

Гомумтюркологик хезмәтләрдә, саннарның этимологиясен тикшерү аларның һәр төркемчәсенә хас булган күрсәткечләренә гигезләп алып барыла [Сравнительно-историческая грамматика..., 1988, с.162–201]. Татар телендә бу юнәлеш Л. Җәләй хезмәтендә дәвам ителә: «Сан исемнәренең этимологиясенә карата юрамалар», – дип, бердән унга кадәр һәм һәр дистәгә, саннарның килеп чыгышына караган мәгълүмат бирелә, хәзерге татар теле белән чагыштырылып, иске татар телендә кулланылышындагы үзенчәлекләре аңлатыла. Микъдар саны, тәртип саны, бүлем саны, чама саны, өлеш саны, җыю саны дигән төркемчәләре һәрберсе аерым тикшерелә. Өлеш саны махсус аңлатылмый [Җәләй, 2000, б. 81–116].

«Языки мира: Тюркские языки» хезмәтендә (1997) һәр телдә кулланыла торган саннар төркемчәләре буенча тикшерелә. Иске татар телендәге истәлекләрне өйрәнүчеләр, шул әсәрдә кулланыла торган саннарның ничек файдаланылуын анализлый. Димәк, XIX йөзнең беренче һәм икенче яртысында язылган тезмә әсәрләрдә, шулай ук XX гасыр башына кадәр язылган чәчмә әсәрләрдә кулланылышта булган саннарны шул ук нигездә тикшерергә кирәклек аңлашыла. Төркемчәләрнең тәртибе төрле авторда төрлечә күрсәтелә, бу очракта «Татар грамматикасы. Морфология»дә бирелгән классификация нигез итеп алынды [Татар грамматикасы, 2002, б. 72–90].

Микъдар саны, хәзерге әдәби телдәге кебек үк, Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви-әс-Сәгыйди» әсәрендә дә (1845, 1889), аерым сүз, сүзформа, сүзтезмә, сүз тезмәсе буларак, предметларның микъдарен белдереп, исемләшеп, ягъни исемгә хас категорияләрдә кулланыла: ике әлчүкәзләрен, ике пул, бер илкеңә, фетнәдер берсе, икесен замм әйләр исәм [Каргалый, 1889, б. 2]; ...бер заман, ике парә, бер капуны [Каргалый, 1889, б. 3]; бу икедән [Карга-

лый, 1889, б. 4]; бең җәфа, сәд һәзари [Каргалый, 1889, б. 5]; һәзарән шөкер [Каргалый, 1889, б. 7]; йөз бең ир иде болар [Каргалый, 1889, б. 10]; ике ғәләм, илле көн [Каргалый, 1889, б. 12] һ.б.

Текстларда саналмыш эзлекле рәвештә берлек санда күрсәтелә, күплек санда булырга да мөмкин: қырық кәниз, қырық кешеләр қачдылар [Каргалый, 1889, б. 10] һ.б. Күбесе төрки-татар теленең сүзләре булган сан исемнәре, үзләре бәйләнгән саналмышының исәбен, микъдарын белдерә, төзелешләре буенча гади, кушма һәм тезмә формада кулланылалар.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыль адәб» җыентыгында (1856) да микъдар саннарның кулланылышы традицион юнәлештә бара: ...Буның тәмсиленә бән бер хикәят, Бәйан идәм, ишет сән, қыл дирайәт, Будыр чықмыш ике ахмақ сәфәргә, бере дийер... [Татар әдәбияты, 1957, б. 53]; ...бере йатды, бере сақлап утырды, чебен басмыш тәмам ике күзене, ... әленә алды бер олуғ таш [Татар әдәбияты, 1957, б. 54]; ...басып ике айақы берлә йөзен, ул чықарды аның ике күзен, ... ике күзе йуқ йирендә, ... ике күзең кәтде қанда [Татар әдәбияты, 1957, б. 55] һ.б.

Ш. Зәки шигырьләрендә: Уйан, йөз мең хәтәр яныңдадыр [Зәки, 2002, б. 29]; Гәр қылырсән дөнйада мең йыл қарар, Ғақыйбәт, җан бирәсәң сән, зар-у-зар [Зәки, 2002, б. 30]; бу дөрре бер йибә тезмәк кирәкдер [Зәки, 2002, б. 31]; Йә Иляһы, бер нәзар қылғыл бу үлмеш күңлемә, ... ачты фикрем тависы ике қанатын [Зәки, 2002, б. 35] һ.б. Эзлекле итеп укып барганда, *бер* санының үз мәгънәсе белән дә, билгесезлекне белдереп тә кулланылуы күренә.

Г. Кандалый шигырь һәм поэмаларында да, микъдар саннары файдалануда традиция дәвам ителә: сачәк бер wақыт атадыр [Кандалый, 1988, б. 72]; буйы булыр ике қарый [Кандалый, 1988, б. 82]; буламы йылда биш көне тыныч, эшсез [Кандалый, 1988, б. 83]; кесәгә ун тиен қунғач [Кандалый, 1988, б. 97]; унике күркә бер этәчне қайчан җиңмәс [Кандалый, 1988, б. 104]; матур қызның қадре китә йегерме йәшенә йиткәч [Кандалый, 1988, б. 147] һ.б.

Текстларда микъдар саннарының исемләшеп кулланылуы да күзәтелә: йегермесен сатып унға [Кандалый, 1988, б. 97]; бергә йөрсәк иде икемез уйнап-көлеп [Кандалый, 1988, б. 114]; бу икеләре ғыйлем булса [Кандалый, 1988, б. 175] һ.б.

*Бер* саны үзенең төп функциясендә кулланыла. Шуның белән бергә, төрле төсмерләр белән дә файдаланыла. Билгесезлек төсмере белән: ...Ки җәй фаслында бер ирне һаwа сукса хәрарәтдән [Кандалый,

1988, б. 84]; йәнә йанында бер мәхбүб утыра [Кандалый, 1988, б. 86]; йөрер идем бер заманда қәрйәдә [Кандалый, 1988, б. 134] һ.б.

Билгелелек төсмере белән: бер қашық ашымны [Кандалый, 1988, б. 105]; Бер Ходайдин бән сорыймын сәне даим, Теләкләрне қабул кылсын бер Ходаем [Кандалый, 1988, б. 109]; ишет ки бер үгетемне биш ит [Кандалый, 1988, б. 142] һ.б.

*Бер* саны предметның сыйфатын белдереп, аергыч функциясендә килә: фирақлек бер бәла икән [Кандалый, 1988, б. 89]; бер генә кич керә калсам, әй, қуйныңа [Кандалый, 1988, б. 115]; бер тәбәссем садир улса [Кандалый, 1988, б. 134] һ.б.

*Бер* саны рәвеш (хәл) функциясендә: қауышыр көн булырмы бер [Кандалый, 1988, б. 117]; бәйан идәм сәңа бер-бер [Кандалый, 1988, б. 86] һ.б.

*Бер* саны кисәкчә функциясендә: Тарсынма бер дә, китәрмен: җен, Иблистән дә битәрмен [Кандалый, 1988, б. 75] һ.б.

Г. Чокрыйның «Замме назыйр» әсәрендә (1888) төрле хәләхвәлләргә бәйле рәвештә, төрле төзелештәге микъдар саннары кулланыла: Мең сигез йөз дә қырық өч сәнәсендә рузгяр, ... унсигез йәшдә зөфафы, ... биш хатын андағ эшне қыла белмәс, ... мәрхүмәдән өч уғыл вә өч қызы қалды, ... дөнйадин күчкән көнендә утыз алты йәш иде, ... бер қыз илә ике уғыл һәм мөқәддәм қуйды дар, ... дүрт йанында биш сабыйлар чөн мәлаик кундылар [Гомәров, 2006, б. 116] һ.б.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә (1892): биш йөз йылгы батырларны талдырған ул [Акмулла, 1892, б. 3]. *Бер* саны билгесезлек төсмерен белдереп кулланыла: Қазанда бер фазыйл чықды алмас булыб [Акмулла, 1892, б. 2]; мин бер арық бүредәй җилеп йөргән, йәшдә җыйған бер буаз мәҗмағым бар [Акмулла, 1892, б. 3]; бер шәриқ қалын китаб остаб торса [Акмулла, 1892, б. 4] һ.б. *Бер* саны исемләшеп файдаланыла: берәwе қулға төшсә, бере төшмәй [Акмулла, 1892, б. 3] һ.б. Бу әсәрдә *бер* саны тезмә ясап файдаланыла: бер-береннән [Акмулла, 1892, б. 289]; бер-берсенә [Акмулла, 1892, б. 299]; бер-береңезгә [Акмулла, 1892, б. 301]; бер-беренә [Акмулла, 1892, б. 303] һ.б.

Г. Тукайның шигырьләрендә *бер* санының микъдарны белдереп тә, билгесезлек төсмере белән кулланылуы да дәвам итеlә. Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә кулланыла торган саннарны «Г. Тукай. Шигърият теле» дигән хезмәткә (2009) нигезләнеп аңлату кабатлану ешлыгын төгәл итеп күрергә мөмкинлек бирә. *Бер* сүзе 636 мәртәбә

файдаланыла, сүзформа, сүзтезмә, кушма сүзләр формалаштыруда катнаша [Тукай, 2009, б. 147–163]. *Бер* түбәндәге мәгънәләрдә кулланыла. Микъдар мәгънәсендә: Улалым җөмләмез бер йула ғазим [Тукай, 1985, б. 35]; Улыб бер сүздә бер дәртле җәмәғәт [Тукай, 1985, б. 38]; Бүлик без бер алманы [Тукай, 1985, б. 45]; Бер җан, бер тән булып [Тукай, 1985, б. 122] һ.б. Билгесезлек мәгънәсендә: Шималь йақтан чығып бәрқ, орды бер нур [Тукай, 1985, б. 34]; Бу көндә бер сарай ачды әһали [Тукай, 1985, б. 37]; Менә дустлар, мин сезләргә бер сүз сөйлим [Тукай, 1985, б. 42] һ.б.

Алдагы шагыйрьләрдән аермалы буларак, Г. Тукай, күпчелек очракта, *бер* саны белән билгесезлеге белдерелгән исемне, шигырь эчтәлегендә тәгаенләп сурәтли: Нәқ Қазан артында бардыр бер аwыл – Қырлай диләр» [Тукай, 1985, б. 168–169] һ.б.

Г. Тукай шигъри әсәрләрендә *бер* санының башка төркемчәләрне, алмашлык, рәвеш сүз төркемнәре, тезмә исемнәрне хасил итеп һәм исемләшеп файдаланылуы күзәтелә: бер-беребездән қачмыйқ, қайчанға чақлы татар, бер-берсенә уқ атар [Тукай, 1985, б. 45]; бераз яздым [Тукай, 1985, б. 84] һ.б. *Мең* саны белән азлык һәм күплек төшенчәләре аңлатыла: Ишек баwы бер алтын, Безнең апай мең алтын [Тукай, 1985, б. 196] һ.б.

*Ике* саны Г. Тукай шигъриятендә 39 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, 333–334]. Сүзформа халәтендә тәртип, җыю төркемчәләрендә, *бер, өч* саннары белән тезмә чама саны хасил итеп һәм исемләшеп файдаланыла: Безнең байның ике күзе йалтырады [Тукай, 1985, б. 194]; ...Бәйрәм көнне күктән җиргә нурлар аға, Әйтерсең лә чыққан бу көн ике қойаш! [Тукай, 1985, б. 205]; йарылмас ай икегә [Тукай, 1985, 2, б. 50]; Бу икене қумақлыққа булсын қарар [Тукай, 1985, 2, б. 87].

*Өч* саны Г. Тукай шигъриятендә 26 мәртәбә кулланыла. Сүзформа буларак, тәртип, бүлем сан төркемчәләрендә, *ике, дүрт* саннары белән тезмә бүлем, чама саны буларак һәм исемләшеп файдаланыла [Тукай, 2009, 2, б. 83]: Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай – өч йолдыз ул [Тукай, 1985, 2, б. 233] һ.б. *Йөз* саны белән тезмә ясап кулланыла: Тулды өч йөз йыл Романов нәсленә [Тукай, 1985, 2, б. 268]. Исемләшеп файдаланыла: Өч хақиқәт шул иде, Һәр өче мәқбуль иде [Тукай, 1985, 2, б. 256] һ.б.

*Дүрт* саны 20 мәртәбә кулланыла. Сүзформа хәлендә, тәртип, бүлем төркемчәләре мәгънәсендә, *алты, ун* саннары белән тезмә чама саны буларак һәм исемләшеп файдаланыла [Тукай, 2009, б. 284–285]:

Бәхтийәрсән дүрт җәридә сахибе улмақла сән, Чөн ақар һәр дүрт тарафдан мәғрифәт нәһәри сәңа [Тукай, 1985, б. 98]; Алды дүрт йағымны йалқын, йақмады, харқ итмәде [Тукай, 1985, б. 183]; Мә, кирәксә, дүртеңә дүрт йозрығым [Тукай, 1985, 2, б. 213] һ.б.

*Биш* саны 13 мәртәбә кулланыла. Сүзформа хәлендә, тәртип, бүлем төркемчәләре мәгънәсендә, *алты* һәм *ун* саны белән тезмә чама саны буларак һәм исемләшеп файдаланыла [Тукай, 2009, б. 176–177]: Бу рәwештә үтте-китте биш сәнә [Тукай, 1985, б. 78]; Көн дә биш намаз уқый [Тукай, 1985, б. 91]; Биш намаз сайын намаз әһленә қул сузып кала [Тукай, 1985, б. 146] һ.б. *Йөз* саны белән тезмә ясап кулланыла: Инде қалды барчабыз биш йөз генә [Тукай, 1985, б. 271] һ.б.

*Алты* саны 11 мәртәбә кабатлана. Сүзформа хәлендә тәртип саны, *биш-алты* формасында тезмә чама саны булып файдаланыла [Тукай, 2009, б. 51]: тағы алты хатын алыр, тағын да алыр [Тукай, 1985, б. 102]; Үлеп торсам иде мин алты айдай [Тукай, 1985, б. 110] һ.б. *Йөз* һәм *мең* саны белән тезмә сан ясап кулланыла: Алты йөз башлы йыланнармы кирәк [Тукай, 1985, б. 268]; Бауның алты мең қолачлы буйы бар [Тукай, 1985, б. 269].

*Җиде* саны 3 мәртәбә, ике мәртәбә тәртип саны, бер мәртәбә бүлем саны буларак кулланыла [Тукай, 2009, б. 299]: Җиде қат боз астыннан чығар бақа [Тукай, 1985, б. 55]; Җиде көне-төне чөнки киттеләр [Тукай, 1985, б. 268]; Үтә бер көн, ике, өч, дүрт, үтә җиде, сигез көндә [Тукай, 1985, б. 289] һ.б.

*Сигез* 6 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, 2, б. 122]: Татарлар рәфғәте, шаны сикез қат күкләрә китсен [Тукай, 1985, б. 24]; Дөнйадуқ нишләп ача ул сигез оҗмах қапқасын [Тукай, 1985, 2, б. 195], Җәбраил ачқай ул эшләргә сигез қат күккә йул [Тукай, 1985, 2, б. 216] һ.б. *Ун* саны белән кушма сан ясала, исемләшеп кулланыла: Шул зинданда үсеп җиттем унсигезгә [Тукай, 1985, б. 203].

*Тугыз* саны 2 мәртәбә файдаланыла [Тукай, 2009, б. 210]: Туғыз қорбан суйып алған қорбан сез [Тукай, 1985, б. 126]; Мин хаҗи бардым хаҗә туксан тугыз [Тукай, 1985, б. 263].

*Ун* саны 10 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, 2, б. 241]. Г. Тукай шигъриятендә *унбер, унике, унөч, ундүрт, унбиш, унсигез* кушма саннары да күзәтелә: Ун йәш тулғач, унбер йәштән күрдем зиндан [Тукай, 1985, б. 202]; Қурыққаны: үксез қала ике бала, Нигә қурқыйм? Қалсын унике бала [Тукай, 1985, б. 79]; Мондағы ун урнына ул җирдә унбиш шпион [Тукай, 1985, б. 186]; Бу шәһәрнең Думасында

ун сәнә [Тукай, 1985, б. 263]; ...Бу мидә бардыр җәһаләт ун вагон [Тукай, 1985, б. 265] һ.б.

*Егерме* саны 2 мәртәбә кабатлана: Һәр җәдит-кяфер – йегерме склад [Тукай, 1985, б. 265]; Торды йәшереп нәк йегерме йыл тәмам [Тукай, 1985, 2, б. 256].

*Утыз* саны 5 мәртәбә кабатлана: Хат белән бергүк утыз сум акча салған берйулы [Тукай, 1985, б. 237] һ.б. *Биш* саны белән тезмә булып файдаланыла: Утыз биштә мәхәллә башы булдым [Тукай, 1985, 2, б. 332] һ.б.

*Қырық* саны 2 мәртәбә кабатлана: Күрәмсез: бу қырық башлы чайан бит [Тукай, 1985, б. 108]; Қырық йәштә Дума әғасы булдым [Тукай, 1985, 2, б. 332].

*Җитмеш* саны бер мәртәбә кулланыла: Җитеп килә инде анық җитмеш йәше [Тукай, 1985, 2, б. 68].

*Сиксән* саны бер мәртәбә кулланыла: Башындағы чабатаңның сиксән сигез серкәсе [Тукай, 1985, б. 251].

*Йөз* саны 27 мәртәбә кабатлана: Бер қабып қуйсаң биш, ун, йөз мең белән [Тукай, 1985, 2, б. 252] һ.б. *Милион* саны белән тезмә ясый: Қотлыйдыр йөзләрчә милион адәмең [Тукай, 1985, 2, б. 269].

*Бең* саны 2 мәртәбә кабатлана: Тәәссеф, йөз тәәссеф, бең тәәссеф! [Тукай, 1985, б. 52]; Чебен җанымны чын йулда бирәм бең кәррә, қызганмыйм [Тукай, 1985, б. 93].

*Мең* саны 16 мәртәбә кулланыла, күплек төшенчәсен белдерү мәгънәсе төрлечә көчәйтелеп файдаланыла:

1) кабатланып кулланыла: Тәңрегә мең-мең шөкерләр қылдылар [Тукай, 1985, б. 276]; Күз алдымда күрәм мең-мең қәдәр йәшерен җиһаннарны [Тукай, 1985, 2, б. 13];

2) бер санына каршы куела: Бер қәдер кич Тәңре қаршында мең айдан изгерәк [Тукай, 1985, 2, б. 188]; Бер сүзең – мең қанлы қоллар ғафведер, Бер ишарәң – мең җинайәт мәхведер [Тукай, 1985, 2, б. 269] һ.б.;

3) башка саннар белән тезмә ясый: Бурычқа йөз мең алғач [Тукай, 1985, б. 91]; Бауның алты мең қолачлы баwы бар [Тукай, 1985, б. 269] һ.б.;

4) иске авырлык үлчәү берәмлеге *пот* сүзе һәм абстракт мәгънәле сүзләр белән бергә кулланылып, авторның ирониясенә төрелгән күплекне белдерә: Чөнки бар мең пот тәғәссеб бу мидә, Бу мидә мең пот сыраның пары бар [Тукай, 1985, б. 265] һ.б. Шулай итеп, тезмә

әсәрләрдә микъдар саннары үзләренең төп мәгънәләрендә һәм сурәтләү чарасы буларак синтагматик мәгънәләре белән файдаланылалар.

Тәртип саннары да актив кулланылышта була. Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә (1845) тәртип саннары хәзерге әдәби телдәге кебек *-ынчы/-енче (-нычы/-нече)* кушымчалары белән языла. Саба дигән шәһре-шәрифнең ни өчен җир өстендәге җәннәт кебек булуын аңлатканда, *икенче, өченче, сәкезенче, тукызынчы, унберенче, уникенче* дип, аның унике хикмәте булуын саный, ягъни тәртип саннарын куллана, шуларның алтысы төрки-татарның үз сүзләре белән, калганнары *әүwәлән, чар-чәһар, хамисән, садисән, гаширән* дип, гарәп-фарсы алынмалары белән белдерелә, җиденче саны күренми [Каргалый, 1889, б. 7–8]. Әлеге әсәр ун хикәят итеп языла, алар гарәп алынмалары белән саналып исемләнә: *хикәйәте әүвәл, хикәйәте сани, хикәйәте салис, хикәйәте рабиғ, хикәйәте хамис, хикәйәте садис, хикәйәте сәбғ, хикәйәте сәмин, хикәйәте тәсиғ, хикәйәте гашер д*ип, барлык хикәятләре дә алынмалар белән исемләнә. Хак эшен инкяр итүчеләр саналганда да, алынмалар файдаланыла: Әүwәлән, Шәйтан иде инкяр иткән, Нәчә бең ел тәғәтен бадә вирән, Санийән, Фиргавен, Нәмруд, ибн Ғәд, Бонлар улды дөнйада әһле ғыйунад [Каргалый, 1889, б. 11] һ.б. Шулай итеп, Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә, микъдар саннарына караганда, тәртип саннарын белдерү өчен, гарәп-фарсы алынмаларының күбрәк кулланыуы күренә.

Башка авторларның тезмә әсәрләрендә тәртип саннары, асылда, хәзерге әдәби телдәге кушымчалары белән күрсәтелә. Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыл адәб» җыентыгында (1856): варып икенче күзен вирде ул зар [Татар әдәбияты..., 1957, б. 56] һ.б.

Г. Кандалый шигырьләрендә тәртип саны исемләшкән хәлдә файдаланыла: Тутыр бик яхшы корсакны, Икенче қалмасын соңға [Кандалый 1988, б. 97] һ.б.

Г. Чокрыйның «Замме назыйр» әсәрендә (1888): Балалары иза қылса –икенчедер, Анлар ахмақ булыр булса – өченчедер, Зәғиф, мохтаҗ булыр булса – дүртенчедер, Балиғ булғач ташлаб чықса – бишенчедер, Дошманына хадим булса – алтынчыдыр, Бала үзе дошман улса – йитенчедер [Гомәров, 2006, б. 142] һ.б.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә (1892): Иң әүвәл кирәк нәрсә – иман дигән, Ахирәт эшләренә инан дигән, Икенче қыйммәт нәрсә – күңел дигән, Күңеле бозық

адәмнән түнгел дигән, ... Өченче қыйммәт нәрсә – ғақыл дигән, Ғақылсызда тәүфиқ җағы тақыр дигән, ... Дүртенче қыйммәт нәрсә – шөкер дигән, Ниғмәткә шөкерсезлек көфер дигән, ... Бишенче қыйммәт нәрсә – әдәб дигән, Әдәб дигән – мәхәббәткә сәбәп дигән, ... Алтынчы қыйммәт нәрсә – сабыр дигән, Сабыр кеше морадын табыр дигән, Һәр эштә сабырсызның төбе – хурлық, Сабырсызлық башқа бәла салыр дигән! [Акмулла, 2001, б. 84–85] һ.б.

Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә *бер* саны тәртип саны формасында 7 тапкыр файдаланыла [Тукай, 2009, б. 159]: Аwыл җырлары (беренче көлтә) [Тукай, 1985, б. 219]; бу дөнйада беренче патша дип саный [Тукай, 1985, б. 286]; Олуғ уғлын шуларға баш – беренче пәһлеwан қылды [Тукай, 1985, б. 289]; Беренче кәррә мөмтаз булса [Тукай, 1985, 2, б. 101] һ.б. Шул ук мәгънәдә: әүwәл уларақ (беренче булып) чыққан журнал ирер [Тукай, 1985, б. 27] һ.б. *Ике* саны тәртип формасында 9 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, б. 334]: Икенче бер көндәш исмен дәшкән була [Тукай, 1985, б. 204], Икенче қул белән Хурлар қочам мин [Тукай, 1985, б. 243]; Аwыл җырлары (икенче көлтә) [Тукай, 1985, б. 251]; Үтә бер йыл тынычлық берлә, үтмәктә икенче йыл [Тукай, 1985, б. 288] һ. б. Икенче саны *-лап* кушымчасы белән фигыльне ачыклап килә: Йосыб китте сәяхәткә, Рәшит икенчеләп китте [Тукай, 1985, 2, 18]; Мәмәт инде өченче ғаскәре белән үзе китте [Тукай, 1985, б. 289]; Өч баш хатынлы иде ул, мин – дүртенче, Җыйылыштық бер тар йортқа без дүрт көнче, Кисеп әйтә алмыйм әле дүртенче дип, Мин булганмын, бәлки, инде ундүртенче [Тукай, 1985, б. 203]; Өчдүрт бүре берсе соңра қача берсе, Өченчесе, аннан соң дүртенчесе [Тукай, 1985, 2, б. 89]; Соңра алтынчы сәнә килде йәнә [Тукай, 1985, б. 78]; Була қалсаң җиденче, хәл начар қыз [Тукай, 1985, б. 102]; Менә сигезенче таң атқанда хан туқтады бер тауға [Тукай, 1985, б. 289], ник бу йегерменче ғасырда йөз дә йук [Тукай, 1985, 2, б. 205] һ.б.

Җыю саны хәзерге әдәби телдә *-ау/-әү* кушымчасы белән ясала. Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә исә язма традиция дәвам ителеп, җыю саны *-ләсе* кушымчасы белән дә бирелә: Талиғы мәсғуд иде Мәхмүд хан, Атасы ирде аның мәрхүм Хәмид, Һәр икәләсе шәриф һәм сәғид, Үзе мәнсур, талиғы ирде қави [Каргалый, 1889, б. 12]. «Кыйссаи Йосыф»та: Икеләсе шәһәр ичрә билә керде, Уныласы wармага ғазем кылды һ.б. [Җәләй, 2000, б. 116].

Берсе, икесен замм әйләр исәм [Каргалый, 1889, б. 2]; ...ир вә гәүрәт – һәр икесен, зари-зар ағлатып, буып йиде бичараларны

[Каргалый, 2002, б. 105] дигән җөмләләрдә *-се* кушымчасы белән җыю төшенчәсе белдерелә булса кирәк. Билгеле бер контекстта *-е* кушымчасы да шушы вазифаны башкара кебек: ...Бу дүрт нәснә сәңа Хақтан, Ғатадыр, әй күзем нуры, Бере-хөснең, бере – холкың, Бере – лотфың, бере – ихсан [Каргалый, 2002, б. 123] .

Ш. Зәкинең «Эстәсәм...» дип башлана торган шигырендә җыю саны шул ук *-лә* һәм *-се* кушымчасы белән ясала: җан илә иман икәүлән бер өйдә бал эчәләр, ... ул икесе бер өйдә булғай-булмағай [Юсупов, 2006, с. 75, 188].

Г. Кандалыйның шигырьләрендә, хәзерге телгә хас булганча, *-ау/-әү* кушымчалы саннар кулланыла: икәү бергә йөреп ашқа, ғомергә көлкегә қалдың [Кандалый, 1988, б. 98]. *-лап/-ләп* кушымчасы кушылып, бергәлек мәгънәсе көчәйтелә: абыстай берлә икәүләп, мужикның сыртын игәүләп [Кандалый, 1988, б. 98]; Болай торғанча икәү ары-бире, Қушылайық икәүләп китмә кире [Кандалый, 1988, б. 151] һ.б. Җыю төшенчәсе *-сы* кушымчасы белән белдерелә: Шул айырылу белән үлем, Икесе булмаса иде [Кандалый, 1988, б. 94], утырыр икесе алда, самаварны алып алға [Кандалый, 1988, б. 178]. *-лә* кушымчасы белән: бу икеләре ғыйлем булса [Кандалый, 1988, б. 175] һ.б.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә (1892) *-ау/-әү* кушымчалы саннар: берәүе кулга төшсә, бере төшмәй [Акмулла, 1892, б. 2]; берәүгә морад булса Хақның йәде [Акмулла, 1892, б. 4], берәүне йаманларға қандай оста [Акмулла, 1892, б. 10] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, *-ау/-әү* кушымчалы *берәү* саны җыймалык төшшенчәсен белдерә дип әйтеп булмый, сүз монда билгесезлек төсмере белән әйтелә торган бер зат турында бара. Әлеге мәсьәлә хәзерге грамматикаларда төрлечә аңлатыла. В.Н. Хангилдин хезмәтендә, К. Насыйри фикере [Насыйри, 1975, б. 12] кабатлана: «Сөйләшү телендә *-ау/-әү* кушымчасы ялганган форманың да төп сан ролендә кулланылуы бар» [Хангилдин, 1954, б. 125], «Икенче яктан, шул ук формадагы саннар, күбесенчә, төп санны түгел, бәлки җыю, бергәлек төшенчәсе катнашкан санны белдерү өчен кулланылалар», – диелә [Хангилдин, 1954, б. 131]. Шул ук вакытта: «Берәү сүзе бөтенләй алмашлыкка күчә (прономинализация)», – дип белдерелә [Хангилдин, 1954 б. 126]. Хәзерге хезмәтләрдә: «*-ау/-әү* кушымчасы алган сан микъдар саны мәгънәсендә дә кулланыла» [Татар грамматикасы, 2002, б. 81], «...санны предметлаштыра», – дип аңлатыла [Хисамова, 2006, б. 138].

Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә *берәү* формалы сан 12 мәртәбә кабатлана: Инанмаңыз берәү йуқтыр дийерсә бездә шагыйрьләр [Тукай, 1985, б. 184]; Берәү булсаң, ике җан ачысын күрмисең син [Тукай, 1985, б. 192]; Синең төсле берәү ул: бергә-бер сез [Тукай, 1985, б. 232]; Берәү дә бер тийен ақча түләтми [Тукай, 1985, б. 243]; Килеп керсә берәү нәқ шул чағында [Тукай, 1985, б. 253]; Ишеттем мин кичә: берәү җырлый [Тукай, 1985, 2, б. 55] һ.б.

Аңлашылганча, *берәү* сүзен, асылда, микъдар саны мәгънәсендә, саналмышы (кеше) күрсәтелмәгәнгә, исемләшеп кулланыла дияргә, ләкин *берәү җырлый* тезмәсендә, кемдер төшенчәсен атап, билгесезлек алмашлыгы вазифасында кулланыла дияргә мөмкин. Башка саннарда *-ау/-әү* кушымчасы җыймалыкны-бергәлекне аңлата: Нәрсә белсәң дә, икәү уртақлашыйқ аның белән [1985, б. 156], Ичмасам иптәш тә йуқ ич, тик икәү без: уй да мин [Тукай, 1985, б. 158]; Йәш җегет! Килче, икәү уйныйқ бераз кети-кети [Тукай, 1985, б. 170]; Бу өчәү һәрберсе дә үз тормышыннан зарлана [Тукай, 1985, 2, б. 85]; Булса да сүзләр береккән, бу өчәү айырым яши [Тукай, 1985, 2, б. 193]; Дүртәүләшеп, дүрт эт төсле, дөбер-дөбер [Тукай, 1985, 2, б. 203]; Сүзләр қуйыштық, дүртәү суғыштық [Тукай, 1985, 2, б. 257]; Татар байса – хатын асрый, була хатыны өчәү-дүртәү [Тукай, 1985, 2, б. 278]; Безнең өйдә без җидәү: безнең песи – җиденчесе [Тукай, 1985, 2, б. 103] һ.б.

Бүлем саны хәзерге әдәби телдә *-ар/-әр, -шар/-шәр* кушымчасы белән ясала. Ә. Каргалый иҗатында бу форма күзәтелми булса кирәк. Башка шагыйрьләрдә дә сирәк кулланыла.

Ш. Зәки шигырендә: Меңәр гафил, бу сүзе танымаеб китәр кире [Зәки, 2002, б. 31] һ.б.

Г. Кандалыйның шигырь һәм поэмаларында: берәр ашқа баруны сән, үзеңә зур бәхет сандың [Кандалый, 1988, б. 98]. Бу очракта *берәр* сүзенең билгесезлек төсмере белән кулланылуы аңлашыла.

Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә: Көндә ашқа бара унар [Тукай, 1985, б. 90]; Аның чөн йорт саен безнең берәр қомғанымыз бардыр [Тукай, 1985, б. 184]; Бу Дийү һәр көн бишәр адәм суйа [Тукай, 1985, б. 271] һ.б.

Чама саны хәзерге әдәби телдә *-лап/-ләп* кушымчасы белән ясала. Г. Тукай шигырьләрендә дә шундый ук ысулда файдаланыла: Алмышым ғомремдә унбишләп хатын [Тукай, 1985, б. 263]; Бу мидә йөзләп гыйнад амбары бар [Тукай, 1985, б. 265]; Бер түгел, меңләп Қарахмәт килсә дә [Тукай, 1985, б. 265]; Анда биш йөзләп мөселманнар

тулы [Тукай, 1985, б. 271]; Тәңрем, сиңа қылырмын мин меңләп шөкер [Тукай, 1985, б. 261]; Берләп түгел, алтыдин [Тукай, 1985, 2, б. 191]; Бер сөйәккә унлап эт бар, чәйнәшәләр даулашып [Тукай, 1985, 2, б. 186]; Қырықлап басмасы бар – бик аwыр һәм дә озын басқыч [Тукай, 1985, 2, б. 138] һ.б.

Шул ук вакытта, чама санының янәшә саннарны кушып әйтү белән ясала торган тезмә формасының актив кулланылуы күзәтелә: Хәтерең қалмасын, бер-ике сүз әйтим [Тукай, 1985, б. 32]; Бер-ике суқты қазый [Тукай, 1985, б. 282]; Жығылдық без ике-өч чақрым да китми [Тукай, 1985, 1985, 2, б. 133]; Җитмәгәнме бер хатын, өч-дүрт хатын асрау нигә? [Тукай, 1985, б. 240]; Җәмғ улыб өч-дүрт кеше һәр чат саен [Тукай, 1985, б. 273]; Шул турыдан аз ғына – биш-алты сүз сөйлим әле [Тукай, 1985, б. 169]; Бәйрәм өчен биш-ун тәңкә бирче абзый [Тукай, 1985, б. 194]; Биш-алты көн бара: шаһзадәләр дә, ғаскәре дә йуқ [Тукай, 1985, б. 289] һ.б.

Күрсәтелгән чорда иҗат ителгән тезмә әсәрләрдә саннарның барлык төркемчәләренең дә файдаланылуы күренә, әмма аерым төркемчәләр ешрак кабатлана.

XIX гасырның икенче яртысыннан, XX гасыр башына кадәр язылган сәнгатьле чәчмә әсәрләрдә дә саннарның үзенчәлекле кулланылуы дәвам ителә.

Сәнгатьле прозаны хикәяләүнең беренче төренә карый торган чәчмә кыйссаларда микъдар саны. К. Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы»нда (1868): Сарайның эчендә бер бүлмәсенә нәқыш йаса, ул бүлмәнең дүрт йағына да адәм сурәте нәқыш итеп тутыр [Насыйри, 1975, б. 226]; бер табақ бал китерде, мең төрле тәхсин уқыды [Насыйри, 1975, б. 227]; бер патша бар идее, вә ул патшаның өч данә уғылы бар иде, бер қапчық энҗе, атабыз өчебезгә аулақта әйтде [Насыйри, 1975, б. 228]; Хуҗа ул ташны икегә бүлде, Хуҗа ул йартысын дәхи икегә бүлде [Насыйри, 1975, б. 231] һ.б. Мисаллардан *өч* һәм *ике* санының исемләшеп кулланылуы аңлашыла.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда (1881): өч йөз йитмеш өч йыл булыр, дүрт йөз илле дүртдә дөнйадан күчде вә ғомере сәксән бер йәшендә иде [Насыйри, 1974, б. 208]; бер-ике көн анда торып [Насыйри, 1974, б. 209]; өч сәғәт микдары ачық тотыр, өч сәғәтдә ни хасил булыр [Насыйри, 1974, б. 209]; бер йыл шул шәһәрдә қалып, бер дирһәм аwырлыгы, айда бер мәртәбә су эчәрләр иде, бер данәсене қапсалар, қырық көнгә чақлы ашамақ-эчмәк қайғысыны күрмәсләр иде [Насый-

ри, 1974, б. 212]; мең төрле ғөзер вә нийаз кылды [Насыйри, 1974, б. 218] һ.б. *Мең* санының фарсы алынмасы *һәзар* белән чиратлашып та кулланылуы күзәтелә: Әбелхарисқа һәзар тәхсим вә афәриннәр әйтеп [Насыйри, 1974, б. 225] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда (1887): бер Сәғыйд исемле сәүдәгәре бар иде, асла бер баласы килмәгәнлекдән, хәләл малыңдан мең ақча садақа бир, туқыз ай ун көн булғанда бер ир бала дөнйаға килде, дүрт йәшенә йиткәндә [Фәизхан, 1896, б. 3], мең җан белә, бу ике ғашыйқның [Фәизхан, 1896, б. 3], сиксән изге адәм, бер яwыз адәмне изге итә алмай [Фәизхан, 1896, б. 4] һ.б. *Бер* саны, төп мәгънәсенә караганда, билгесезлек төсмере белән ешрак кабатлана, башка саннарның исемләшүе күзәтелә.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Бүз йегет» әсәрендә микъдар саннары, асылда, шундый ук вазифа үтәп файдаланыла: бер хан вар иде, аның бер кызы вар иде, қачан ун биш йәшенә ирешде ирсә, бер көн йатыб төш күрде, бер йекет кәлмеш күрде, бер кеше ниқах қылмыш, икесе бер-берендин айырылмас мәхәббәт дус иде, Бүз йекет шул вакытта унйите йәшендә ирде, һәм қашында қырық қыз бергә кәлмеш [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 2–3] һ.б.

«Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: бер олуғ вә мәшһүр падишаһ бар ирде [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 3]; мең алтын биреп, бер ағачның йанына килделәр [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 288]; берсе падишаһ вә берсе вәзир имеш, һәр икесе бала өчен нийәт қылмышлар, береңез падишаһ вә береңез вәзир, һәр икеңез бала өчен, [Татар әдәбияты, 1957, б. 289]; туғыз ай ун көн тәмам булғанда, биш-алты йәшләренә кергәч, бу икесене меллаға биреп [Татар әдәбияты, 1957, б. 290]; бу икесе бер көн қаршылашып [Татар әдәбияты, 1957, б. 293] һ.б.

Тәртип саннары К. Насыйриның «Кырык вәзир» кыйссасында: бу сүзне икенче мәртәбә әйтмә [Насыйри, 1975, б. 227]; дүртенче көнендә әҗәл ширбәте эчеп [Насыйри, 1975, б. 228]; икенче бер кешегә биргән иде [Насыйри, 1975, б. 235]; өченче ташны қуйып, икенче мәртәбә дәхи бер гөнаһны эшләр [Насыйри, 1975, б. 238] һ.б. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: ...Ошбу Әбүгалисина кыйссасы 1281 нче йылда Казан әһалисендән бер адәмнең һиммәте белән бер мәртәбә табғы қылынмыш иде [Насыйри, 1974, б. 207]; һиҗрәтнең өч йөз йитмеш өченче йылда, бер ата бер анадан игез ике бала дөнйаға килеп [Насыйри, 1974, б. 208]; икенче көн қойашқа қуйып киптерделәр [Насыйри, 1974, б. 212]; зыйафәтнең икенче көнендә

[Насыйри, 1974, б. 225]; сезгә икенче җәһәттән [Насыйри, 1974, б. 229] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда: бер изге нәселле вә хөсне җәмалда беренче дәрәҗәдәге гөл бакчасының чәчәгенә охшаған Маһишәкәр исемле бер гүзәл қызны Сәғидкә никайалап алып бирделәр [Фәизхан, 1896, б. 3] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Бүз йегет» әсәрендә: икенче ел дәхидә бер төш күрде, өченче йыл бу йекет қызны төшендә күреб [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 2–3] һ.б. Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: җиденче көнне шәһәргә керделәр [Татар әдәбияты, 1957, б. 306], өченче көнне күрделәр ки [Татар әдәбияты, 1957, б. 320] һ.б.

Җыю саннары. «Кырык вәзир»дә: артымнан берәүне җибәр [Насыйри, 1975, б. 224] һ.б. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: агай-эне икәүләшеп йөрергә чыктылар [Насыйри, 1974, б. 209]; берәүдән туқтатып сорадылар [Насыйри, 1974, б. 210] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда: ана Тутыйны күреб бер алтынга алыб китереб икесене бергә куйды [Фәизхан, 1896, б. 6] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: ...бу нийәт ийәләренең берсе падишаһ вә берсе вәзир имеш. Һәр икесе бала өчен нийәт қылмышлар, береңез падишаһ вә береңез вәзир, һәр икеңез бала өчен нийәт қылмышсыз, һәр икесен бер җирдә тәрбийәләп үстерәсез [Татар әдәбяиты, 1957, б. 289] һ.б. Аңлашылганча, җыю саны, асылда, традиция булып килә торган *-сы* кушымчасы белән күрсәтелә.

Бүлем саны. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: һәр қоббәдә берәр хезмәткәр тайар кылды [Насыйри, 1974, б. 215]; бу йегетләрнең қырығышар һөнәре бардыр, бу күргәнең берсе генәдер, мондан башқа утыз туғызар һөнәрләре бардыр [Насыйри, 1974, б. 216]; һәрберсенең қырығышар һөнәр вә сәнағате бардыр, дүрт-биш мең миқдар адәм белән ничә һәдийәләр күндереп [Насыйри, 1974, б. 222] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: болар икешәр йәшләренә керделәр, болар унар йәшләренә керделәр [Татар әдәбияты, 1957, б. 290] һ.б.

Чама саны. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: қырықлап һәйбәт гүзәл йегетләрдән [Насыйри, 1974, б. 215] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы» нда: бер-ике көндән Бабил шәһәрендән күп сәүдәгәрләр килеб [Фәизхан, 1896, б. 5] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә чама санының янәшә саннарны кушып әйтү белән ясала торган тезмә формасы кулланыла: биш-алты йәшләренә кергәч [Татар әдәбияты, 1957, б. 290]; қызлар суны күзәтеп бер-ике көн үтте [Татар әдәбияты, 1957, б. 320]; ул хатынға биш-ун алтын биреп, илчене эзләп табып биш-ун алтынны биреп [Татар әдәбияты, 1957, б. 321] һ.б.

Сәнгатьле прозаны хикәяләүнең икенче төренә карый торган мәгърифәтчеләр иҗатында микъдар саны тормышта була торган төрле вакыйга-хәлләргә бәйле рәвештә төрле вазифа үтәп кулланыла.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында: Йөзенә бақсаң бу йегерме биш йәшлек җегеткә тәғәҗҗепләнерсең [Акъегет, 1979, б. 46]; Шәрге шәриф икедән дүрткә қадәр қадын алмаға рөхсәт вирсә дә [Акъегет, 1979, б. 51]; қырық кичә кичтеге үзрә [Акъегет, 1979, б. 54]; фәқирлектән җитмеш қапу [Акъегет, 1979, б. 56]; ике һәфтә кадәр әүwәл [Акъегет, 1979, б. 81] һ.б.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә файдаланыла торган саннар, яшь кыз үлеме белән бәйле вакыйганы җентекләп күрсәтү максатына җайлаштырыла: сабах сәғәт унда [Бигиев, 1991, б. 221]; ...ике бүлмәле нумерә улып, урам тарафында өч тәрәзәсе вар [Бигиев, 1991, б. 222]; нумер эчендә ике өстәл, дүрт стул, ике кресла, бер диван, бер карават [Бигиев, 1991, б. 222], йәше йегерме биш, йегерме алтыдан зийадә түгел иде, йөз мең сум көмеш ақча [Бигиев, 1991, б. 223]; сәғәт дә уникене суқты [Бигиев, 1991, б. 225] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында да вакыйганы сөйләп бару уңаенда саннар актив кулланыла: қәрйәдә өч мәсҗед вә дүрт имамдыр [Бигиев, 1991, б. 254]; Нәкәс мулла ике хатына зәүҗ вә биш балайа атадыр [Бигиев, 1991, б. 255]; шимди исә унбиш-екерме йәшлек уғландан башлап алтмыш-йитмеш йәшенә кәлмеш қартларымыза [Бигиев, 1991, б. 256], мең сәкез данә ат диресе вә дүрт йөз сәксән данә сығыр диресе вирдек [Бигиев, 1991, б. 260] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, кем турында сөйләнүенә карап, аның яше, эше, элек булган, яисә хәзерге хәле саннар белән төгәл рәвештә әйтелә бара.

Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» хикәясендә: икесенең дә берәр қулларында, берсенең башында, ике йағында да [Кәрими, 1996, б. 31]; миннән өч урын арқылы [Кәрими, 1996, б. 32] һ.б. «Нуретдин хәлфә» хикәясендә: гәрчә дисәтинәсен йегерме копеекка қәдәр [Кәрими, 1996, б. 62]; ун йыл мәдрәсәдә ятып [Кәрими, 1996, б. 74] һ.б. «Морза кызы Фатыйма» хикәясендә: менә шундый бер заманнарда

[Кәрими, 1996, б. 80]; Бәкер картның туғыз йәшлек уғылы, унҗиде йәшенә киләрәк [Кәрими, 1996, б. 81]; мең төрле хыйаллар [Кәрими, 1996, б. 82] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: бу тарихтан дүрт йөз йыл элек, ун йыл кәдәр укымыш идем, ике бүлемгә айырмышдыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 266]; йөзләр илә шәкердләр ислам ғыйлемене тәхсил идәләр, Казанда йөз беңнән зийадә җан хисабы улып [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267]; илле йыл артта калған бабаларымыз [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, 270] һ.б.

Тәртип саны. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: икенче бүлмәчегендә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 45]; ғәҗәйеп икенче тәсәдеф [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51]; икенче көн бай мәҗлесендә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53] һ.б. Бу әсәрдә тәртип саннары ярдәмендә автор персонажының фикерләү рәвешен дә тасвир итә: мәхәббәт тарафы бераз көчәйде, беренче: мәктүбенә җаwабы Хәнифә ханым ихсан бойырмыш; икенче: менланың ғашыйк улмасына да инанмыш; өченче: уйлә йазмыш ки, җаwаба җаwап йазмака йул калдырмыш [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 61] һ.б.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә: 11 нче нумерә таш пулатның 2 нче этажында-катында [Бигиев, 1991, б. 222] һ.б. Тәртип саннары, рәсмилекне күрсәтү өчен булса кирәк, гарәп теле алынмалары белән дә бирелә: тәфтиш кылып табылған нәрсәләр, бунлардыр: әүwәлән, бер данә ир пирчәткәсе, саниан, ике тәрәзә арасыннан бер йырткаланмыш патрите-сурәте табылмыш, салисән, нумера эчендән табылған бер мәктүб [Бигиев, 1991, б. 223] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында: икенче мәхәллә имамы карт хәзрәтдер [Бигиев, 1991, б. 256]; икенче бүлмәдә улан кантурайа [Бигиев, 1991, б. 260] һ.б.

Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» әсәрендә: бу рисалә беренче мәртәбә басылып чыкканда, икенче кат бастырырға кирәк булды [Кәрими, 1996, б. 30]; икенче кулларында, икенчесенең башында [Кәрими, 1996, б. 31]; алар өченче класста булырға кирәк [Кәрими, 1996, б. 33] һ.б. «Нуретдин хәлфә» хикәясендә: иң беренче низағ ителә торған бәхәс, икенче йағында башка дөнйа булырға кирәк [Кәрими, 1996, б. 59] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: хәзерендә йәшең унөченчедәдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267]; бәнем өчен дөнйада беренче шатлык [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268];

милади илә 1898 нче ел май аеның 31 нче көне иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 269]; икенчемез мода мөбтәлясе улды, өченчемез үзенең наданлыкларыны дин исеменнән халыкка тәлкыйн әйләде, дүртенчемез, байлар хәтерене калдырмаз өчен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 271], ошбу Багдад илчесе, өч йөз туқызынчы йылда сәфәр айының унберенче кичәсендә, Багдадтан чыгып, өч йөз унынчы йылда мөхәррәм айының уникенче йәкшәнбә көн [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 280] һ.б.

Җыю саны. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: икесенең дә иғтиқатлары [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 63].

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» хикәясендә: икесе ике қулымдан дотып [Бигиев, 1991, б. 227] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында: икәү қәтел қылмышсың икән [Бигиев, 1991, б. 267] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, җыймалыкны белдерү мәгънәсендә *ике* санының, *-се* кушымчасы алган хәлдә файдаланылуы белән рәттән, хәзерге әдәби телдәге формасында да кулланылуы күзәтелә.

Бүлем саны. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: берәр бардак чәй эчәлем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 52]; берәр сәнә ғашыйқлар зәwық вә ғашрәт итеп тордылар [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 86] һ.б.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә: тәрәзәләре икешәр қат [Бигиев, 1991, б. 222]; берәр қасә кофе кәлтүреңез [Бигиев, 1991, б. 228, 231]; берәр сәғәт қәдәр сөйләшеп ултырып [Бигиев, 1991, б. 235] һ.б.

Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» хикәясендә: икесенең дә берәр қулларында [Кәрими, 1996, б. 31]; бәлки ул берәр шәкерттер (билгесезлек алмашлыгы вазифәсында) [Кәрими, 1996, б. 32]. «Нуретдин хәлфә» хикәясендә: унар, йегермешәр десәтинә сатсалар да [Кәрими, 1996, б. 62]; бишәр-алтышар йиргә кереп ашаулары [Кәрими, 1996, б. 75]; сигез йәшләреннән башлап уникешәр йәшләренә кадәр [Кәрими, 1996, б. 77] һ.б.

Чама саны. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә янәшә саннарны кушып әйтү белән ясала торган тезмә формасы кулланыла: шәһәрә анчақ ике-өч сәғәтлек йулдыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 49], егерме-утыз монет ақча [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 65]; биш-алты дәқиқа [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 77]; ике-өч сәғәт кәчте [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 81] һ.б. Саналмышның күплек

санда булуы да чамалыкның якынча микъдарын белдерә булса кирәк: көндез дүрт сәғәтләр вар иде, аwылыннан инде биш чақрымлар китмеш улып [Татар мәгърифәтчелек..., б. 77] һ.б.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә: йәнә биш-ун дәқиқа кәчдекдән соңра [Бигиев, 1991, б. 221]; өч-дүрт йирдә таш пулат ивләре бар, [Бигиев, 1991, б. 226]; бер-ике сәтрә йазу [Бигиев, 1991, б. 226]; өч-дүрт көн кәчкәч [Бигиев, 1991, б. 232] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында: ике-өч көндән зийәдә кәчмәс, унбиш-екерме дәқиқа эчендә [Бигиев, 1991, б. 256], алты-йиде айлык сәфәр [Бигиев, 1991, б. 259]; йиде-сәкез ай ғомренең, бер-ике җомға миқдар қунақ булып, биш-ун рублә ақча [Бигиев, 1991, б. 262] һ.б.

Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» хикәясендә: бер-ике татар килеп җиттеләр [Кәрими, 1996, б. 31]; һәр ел ике-өч ай тәғтил ясап, унбиш-йегерме ел ғомер [Кәрими, 1996, б. 42]. «Нуретдин хәлфә» хикәясендә: җиде-сигез аршин [Кәрими, 1996, б. 63]; биш-ун йыллар мәдрәсәдә яткан [Кәрими, 1996, б. 74] һ.б. «Морза кызы Фатыйма» хикәясендә: өч-дүрт дисәтинә туфрақ иҗарәгә алып [Кәрими, 1996, б. 80] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, Ф. Кәриминең барлык әсәрләрендә дә саннар файдаланыла, әмма аның сәяхәтнамәләрендә тагын да ешрак кабатлануы күзәтелә. «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә: 1899 сәнәсе 15 февральдә [Кәрими, 1902, б. 4], икенче ишарәт вирелде [Кәрими, 1902, б. 4]; бер дәқиқа эчендә бең дөрлү, өч айлық сәйәхәтә кителәйүр [Кәрими, 1902, б. 4]; өченче ишарәт вирелде, вә йиде сәгәт қырық дәқиқада [Кәрими, 1902, б. 5]; беренче мәүқыйғда улан, бер-беремези хәйерләдек, һәр икемез тәфәккерә талдық, дүрт бең сәнәлек [Кәрими, 1902, б. 5]; сәғәт уникеләрә туғры әшйамызы чишеп, беренче, икенче классларда [Кәрими, 1902, б. 154]; хәрәкәтемезең икенче көне 16 февраль, көндез сәғәт унбердә [Кәрими, 1902, б. 7] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: йиде-сигез ғасырлар мөқәддәм [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 277]; бер-ике данә мәдрәсә иптәшләремнән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 269] һ.б.

Сәнгатьле прозаны хикәяләүнең өченче төренә карый торган классик әдипләр иҗатында, һәр әсәрдә кирәк булган дәрәҗәдә, саннар да кулланыла. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» исемле беренче хикәясендә, микъдар саннары тормышта бара торган хәлләргә бәйле рәвештә файдаланыла: һәр йыл

алтмыш тәнкә биреп керергә кирәк, сигез ел уқытсаң, бик күп кирәк шул [Исхакый, 1998, б. 35]; ун кешегә бер кеше бушлай алалар икән, мин илле тәнкә ақча бирәм, ун тәнкә ничек булса да бирсен [Исхакый, 1998, б. 35]; Кәрим абзый илле тәнкә, Әсма абыстай ун тәнкә бирде [Исхакый, 1998, б. 36]; унсигез йәшемдә мәктәпне тәкәммел итеп [Исхакый, 1998, б. 37]; ике билет – бер сум илле тийен, сигез сәғәт барыр [Исхакый, 1998, б. 39] һ.б.

Г. Исхакыйның «Бай угылы» әсәрендә микъдар саннары Кәримнең тормышын сурәтләүдә төп чара буларак кулланыла, аны үлемгә илтә торган сәбәпләрне автор персонажының яшенә мөнәсәбәтле рәвештә тасвирлый бара: Кәрим йеде йәшенә дә йетте [Исхакый, 1998, б. 118]; Кәрим ундүрт йәшенә дә йетте [Исхакый, 1998, б. 127]; Кәрим үндүрт йәшенә йеткәч, хатын-қызға күз қараwы башқарды [Исхакый, 1998, б. 128]; Кәрим унсигез йәшенә йеткәндә қызыл йөзле, қара күзле, курносрак борынлы йегет булып [Исхакый, 1998, б. 135] һ.б.

Г. Исхакый әсәрләрендә файдаланыла торган бу үзенчәлек Ф. Әмирханның «Татар кызы» хикәясендә дәвам ителә. Татар кызының үсә баруына, яшенә бәйле рәвештә, аның яшәеше – хәятенең ничек итеп үзгәрә баруы күзаллана: Татар қызы алты йәшенә җитте. Биш йәшлек энесе, җиде йәшлек ағасы қайwақытта аны чәченнән тартып җылаталар. Татар қызы җиде йәшенә җитте [Әмирхан, 1984, б. 48]; татар қызына өч йыл бер тоташтан [Әмирхан, 1984, б. 51]; татар қызы унөч йәшкә җитте [Әмирхан, 1984, б. 52]; сиңа унбиш йәш тулды, моннан соң ирләргә буйыңны күрсәтеп сабаққа йөрүең ойат, менә сиңа дүрт дивар, миллиард йарым санлы адәм балалары урынына җидесигез җанлы қурчақ һәм атаң булырлар [Әмирхан, 1984, б. 54] һ.б.

Авторның башка әсәрләрендә микъдар саннары үзләренең төп мәгънәләре белән, ягъни предметның санын, исәбен белдереп, еш кына исемнәр кебек үк, килеш, тартым белән төрләнеп тә файдаланыла. «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: Бу кечкенә хикәйә моннан ике йыл әүwәл басылған иде, өч қыз, ике йегет һәм бер қарт әллә нәрсә уйнап утыралар [Әмирхан, 1984, б. 6]; өч көн чыға алмайачақ булғанлықтан, бу нумиры ундүрт сәхифәдә чығадыр [Әмирхан, 1984, б. 9]; ун дәқиқа қщдәр дәwам итте [Әмирхан, 1984, б. 14] һ.б.

*Бер* санының билгелелек һәм билгесезлек төсмере белән кулланылуы дәвам ителә: бер ел исемдә тора [Әмирхан, 1984, б. 6]; уйын бүлмәсенә кергәнемдә бер татар студент [Әмирхан, 1984, б. 9]; өстәлнең бер читендә [Әмирхан, 1984, б. 10] һ.б.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә: ике хәзрәт ғәпләштеләр [Ибраһимов, 1974, б. 403]; бер йолдыз, ике йолдыз [Ибраһимов, 1974, б. 405]; ике кулыны җәйеп, унбиш көнгәчә, өч җомға үткәч [Ибраһимов, 1974, б. 406] һ.б.

Тәртип саны. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» әсәрендә: икенче йыллары бушлай тора алмасмы [Исхакый, 1998, б. 35]; икенче йылда ақчасыз қабул итәрләр, икенче бер мәктәпкә кереп [Исхакый, 1998, б. 37]; икенче тарафтан [Исхакый, 1998, б. 38]; беренче сентябрьдә дәрес башлана [Исхакый, 1998, б. 40]; өченче дәрәҗә булган идем, беренче улдым, беренче булып чықсам, икенче йылға ақчасыз қалырлар, икенче йыл ақчасыз тәхсил итәр, ул йылны беренче булып [Исхакый, 1998, б. 43] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, авторның бу әсәрендә тәртип саннары, асылда, *беренче* һәм *икенче* сүзләре белән бирелә, боларның күбесе, исемне ачыклап, аергыч вазифасын башкара, *ул-, бул-* ярдәмче фигыле белән тезмә хәбәр хасыйл итә.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә: бер шәһәрнең беренче мәхәлләсенең [Ибраһимов, 1974, б. 400]; беренче мөдәррис булачағыны [Ибраһимов, 1974, б. 403] һ.б.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: 4 нче номерында басылған иде [Әмирхан, 1984, б. 6]; «Татар кызы» хикәясендә: бишенчегә бу қызны да сөйәргә мөмкин, икенче хатынлыққа [Әмирхан, 1984, б. 54]; икенче тарафта, әүвәлге сәхифәдә [Әмирхан, 1984, б. 9]; беренче фасыл тәмам булды, концертның икенче фасылы башланды [Әмирхан, 1984, б. 13] һ.б. «Бәйрәмнәр» хикәясендә: дүртенче рәттән дүрт билет [Әмирхан, 1984, б. 23] һ.б. «Танымаганлыктан таныштык» хикәясендә: өченче класс билетларының, икенче класста [Әмирхан, 1984, б. 58, 61]; өстәлнең икенче башында икенче журнални қарап утыра иде [Әмирхан, 1984, б. 60] һ.б.

Җыю саны. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» әсәрендә *-ау/-әү* кушымчасы белән ясалган формасы күзәтелми, *-се* кушымчасы белән күрсәтелә торган түбәндәге саннар җыю төшенчәсен белдерә булса кирәк: өчесе дә бердән, өчесендә дә айырылышу қайғылары урнашуда иде [Исхакый, 1998, б. 54] һ.б.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә: ...өчәүләшеп мәдрәсәгә килделәр [Ибраһимов, 1974, б. 403] һ.б.

Ф. Әмирханның «Бәйрәмнәр» хикәясендә: әнә алар өчесе дә, икесе дә күз дә салмадылар [Әмирхан, 1984, б. 27] һ.б.

Бүлем саннарының Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» әсәрендә файдаланылуы күзәтелми.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: артист халыкка таба берәр мәртәбә бөкрәйде [Әмирхан, 1984, б. 12]; бохари тышлы китаптан берәр җөмлә [Әмирхан, 1984, б. 15] һ.б.

Чама саны. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясендә: дүрт-биш көн элек [Исхакый, 1998, б. 33] һ.б. «Кәләпүшче кыз» хикәясендә: бер-ике йыл укытабыз әле [Исхакый, 1998, б. 54]; бер-ике йыл рәтсез-чиратсыз укуы [Исхакый, 1998, б. 56]. «Бай угылы» әсәрендә: дүрт-биш елдан, унөч-ундүрт йәшенә кәдәр [Исхакый, 1998, б. 117]; бер-ике атна wакыт [б. 123]; утыз биш-кырык йәштә [Исхакый, 1998, б. 151] һ.б.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә: йегерме-утыз адәм [Ибраһимов, 1974, б. 403]; бер-ике стакан салкын чәйдән [Ибраһимов, 1974, б. 405]; бер ун көн-унбиш көн, биш-алты хәлфә булса да [Ибраһимов, 1974, б. 406] һ.б.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: меңләп зыйалы йәш татар йегетләре һәм туташлары [Әмирхан, 1984, б. 7]; йегерме-йегерме ике йәшләрендә [Әмирхан, 1984, б. 12]; кырык-илле йәшендә [Әмирхан, 1984, б. 13]. «Танымаганлыктан таныштык» хикәясендә: бер унбиш дәкыйкалар узгач [Әмирхан, 1984, б. 60]; бер-ике дәкыйкага [Әмирхан, 1984, б. 67]; бер-ике мәртәбә [Әмирхан, 1984, б. 71]; ике-өч ай [Әмирхан, 1984, б. 77] һ.б.

*Кыскача нәтиҗәләр.* Тикшеренүләрдән күренгәнчә, мәгънәсе буенча, бер төрдәге предметларның данә исәбен, микъдарен билгеләп, үзенә генә хас булган, *-ынчы/-енче (-нчы/-нче), -ау/-әү, -ар/-әр/-шар/-шәр, -лап/-ләп* ясагыч күрсәткечләре белән, гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә, лексик-грамматик яктан гомумиләшеп, микъдар (төп), тәртип, җыю, бүлем, чама саны дигән төркемчәләргә берләшә торган сан сүз төркеменең XIX гасырның беренче һәм икенче яртысында язылган тезмә әсәрләрдә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башындагы чәчмә әсәрләрнең һәрберсендә төрлесендә төрле дәрәҗә кулланылышта булуы күзәтелә. Чәчмә әсәрләрдә, чама саны күпчелек очракта, үзара якын торган саннарны кабатлау юлы белән ясалган синтаксик ысулда кулланыла. Классик әдипләр иҗатында, традиция дәвам иткән хәлдә, санның барлык төркемчәләре дә хәзерге әдәби тел нормасында тотрыклылана.

## 5.5. Алмашлык

Махсус әдәбиятта өйрәтелгәнчә, барлык төркем сүзләрне алмаштыра ала дигән мәгънәдә кулланыла торган *алмашлык* сүз төркемен тану һәм билгеләү мәсьәләсе, антик филология тарафыннан ук көн тәртибенә куелган була [Җәләй, 2000, б. 117]. Хәзерге татар әдәби теле грамматикаларында алар, кайсы сүз төркемен алмаштыра алуларына карап, исем алмашлыгы, фигыль алмашлыгы, сыйфат һ.б. дип бүленеп карала. Димәк, алмашлык сүз төркеме дигәндә, мәгънәләре буенча бүленсә дә, объектив чынбарлык күренешләрен атамыйча, бары тик аларга ишарәли һәм кайсы сүз төркеменә мөнәсәбәттә булуына карап, шул сүз төркеменә хас булган гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә лексик-грамматик яктан гомумиләшеп берләшә торган сүз төркеме күз уңында тотыла. Алмашлыклар мәгънәләре буенча бүленә дигәндә, аларның төрле хезмәттә төрлечәрәк бирелүе игътибарны җәлеп итә. «Татар грамматикасы»нда: зат, күрсәтү, сорау, билгесезлек, юклык, билгеләү дип бүлеп тикшерелә [Татар грамматикасы, 2002, б. 305–316]. Ф.М. Хисамова дәреслегендә, әлеге төрләргә «тартым (нисбәтләү алмашлыклары)» өстәлә [Хисамова, 2006, б. 156–157]. В.Х. Хангилдин хезмәтендә: «*...-ныкы, -неке* кушымчасы белән булган алмашлыкларны, ... тартым белән төрләнешенең икенче варианты гына дип аңлатабыз», – дип, аерылып каралмый [Хангилдин, 1954, б. 144]. Хәзерге бүленештә билгеләү алмашлыгының беренче төре дип санала торган *үз* алмашлыгын [Хангилдин, 1954, б. 155; Татар грамматикасы, 2002, б. 316; Хисамова, 2006, б. 152] Л. Җәләй, А.Н. Кононов хезмәте нигезендә, «...кайтымлыклар: кәндем, кәндин, кәнди, үз, үзем, үзең, үзе һ.б.», – дип аерымлый, билгеләү алмашлыгы гомумиләштерүчеләр дип исемләнә. Иске татар телендәге истәлекләрне тикшереүче кайбер авторлар кайтым алмашлыгына игътибар итәләр. Я.С. Әхмәтгалиева зат алмашлыгыннан соң ук «...возвратно-определительные: общетюрк. oz, ozi, kandi, kandozi, ар. xud – сам», – дип мәгълүмат бирә [Ахметгалеева, 1979, с. 109]. А.Р. Исхакова хезмәтендә *үз* һәм *кәнду* алмашлыгы кайтым дип аерылып тикшерелә, билгеләү алмашлыгы «обобщающий» дип исемләнә [Исхакова, 2005, б. 90–91]. Г.Ф. Гайнуллина хезмәтендә дә *кәнду* һәм *үз* алмашлыгы кайтым дип аерылып тикшерелә [Гайнуллина, 2010, б. 81]. Иске татар язма истәлекләрен өйрәнүчеләрнең хезмәтләреннән күренгәнчә, аерым үзенчәлекләр булса да, алмашлыкларның ничек итеп файдаланылуын тикшерү, асылда, хәзерге әдәби телдәге бүленеш нигезендә алып барыла. Димәк, әлеге

юнәлешне дәвам итәргә, әмма аерым әсәрдәге кулланылыш үзенчәлегенә ныграк игътибар итәргә кирәк була. XIX йөзнең беренче һәм икенче яртысында иҗат ителгән тезмә әсәрләрдә, шулай ук XX гасыр башына кадәр язылган чәчмә әсәрләрдә дә, тартым һәм килеш кушымчаларын алып, *үз* алмашлыгының актив кулланышта булуы күзәтелә, шуңа күрә аерым төркем дип тикшерү зарурлыгы күренә.

Зат алмашлыклары дигәндә, хәзерге әдәби телдә, *мин, син, ул, без, сез, алар* кебек өч затның берлек һәм күплеген белдерә торган алты сүз истә тотыла. XIX гасырның беренче яртысында иҗат ителгән тезмә истәлекләрдә дә, асылда, шул ук алмашлыклар файдаланыла. Әмма угыз һәм кыпчак тибындагы графо-орфографик тәртипкә нигезләнеп язылышы ягыннан караганда, аларның вариантлылыгы арта.

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә: сәндин [Каргалый, 1889, б. 2]; мән, бәндин, сәне, аңа, теләйүр андин [Каргалый, 1889, б. 3]; вармыдыр бездә тәгам, виреб аңа, йар мән, безләр өчен, без аны, без дәхи, дөнйадин кичер бези [Каргалый, 1889, б. 4]; анларның бостанына [Каргалый, 1889, б. 9] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, беренче зат һәм өченче зат алмашлыгының күплек саны, төрле килеш кушымчалары алган хәлендә кабатланып кулланылган. *Мән* формасы авторның, «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендәге кебек үк, кайбер шигырьләрендә *бән* белән чиратлашып бирелә.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыйль адәб» хезмәте: сәнең исемең, җәмиғ ғәләмнең сән Ходасы, безә қатаң илә нәвалең, мөвәххидмез сәни мәғбудлегеңдә, ғыйбадәт әйлийәмез сәңа анчақ, безә қоллықда кәндүзең мөғайин ул, ғобудийәт йулын безә мөбәййин ул [Салихов, 1856, б. 2]; بنم – бәнем, بوني – буны, بنكا – бәңә, بن – бән, بنكا – бәңә, بني – бәне [Салихов, 1856, б. 3]; بنكا – бәңә, بنكا – бәңә, بني – бәне [4], بني – бәне, بنكا – бәңә, بنم – бәнем, بني – бәне, بنكا – бәңә [Салихов, 1856, б. 5]. «Һидайәт вир бәңә, йа Раббе» юллары кабатланып барганда, рәттән بنكا – бәңә сүзформасы кулланыла [Салихов, 1856, б. 6–11]. Аннан соң рәттән بنكا – бәңә, بنم – бәнем язылып китә һәм бер-ике урында منكا – мәңә [Салихов, 1856, 5], منمتيك – мәнем тик [Салихов, 1856, б. 12, 13]. Аңлашылганча, беренче зат берлек сандагы алмашлык, эзлекле рәвештә [б] тартыгына башлана, ягъни төрки-угыз язылышы әдәби норма буларак дәвам итә, кыпчак-татар [м] тартыгының язуда бирелеше вариант булып кулланыла. Өченче зат *ул, у, уларың, аны, аның, анлар* формаларында кулланыла: У берне күр, ул ике күзен чыкарыр

[Татар әдәбияты, 1957, б. 56]; гәбаир күрсә ул, бер шәйгә санмаз, җәнабенә уларың рәфғ ителсә, хәласен эстәер булса у тағы, гәр анлар үзләре чыкса сәфәрә [Татар әдәбияты, 1957, б. 58]; улыбдыр мөбтәлә бу эшдә анлар, аның хөкмене, хилаф итсәң уларға, анлары кемдер сәвисәр [Татар әдәбияты, 1957, б. 60] һ.б.

Ш. Зәки шигырьләрендә *бән, мән, без, безләр, сән, сез, сезләр, ул, анлар* кебек зат алмашлыкларының һәм аларның килеш белән төрләнеше А.Йосыпов хезмәтендә анализлана [Юсупов, 2006, с. 63–65].

Ә. Каргалыйның шигырь һәм поэмаларында зат алмашлыкларының кулланылышында, традиция дәвам ителә, әмма сөйләмә формалар да активлаша: мин сабырсызны [Каргалый, 1988, б. 73]; бән сезгә, сез безгә, буздә, бәнем [Каргалый, 1988, б. 74]; миңа бердер, сез наданнарны [Каргалый, 1988, б. 76]; бән күрмәгәй идем, бән қәләм алдым [Каргалый, 1988, б. 77]; бәнем эчемдәге нарым [Каргалый, 1988, б. 78]; бәнем қәдрем [Каргалый, 1988, б. 79]; сорап сези, әйа балам, сорыйм сези [Каргалый, 1988, б. 91]; сәнең тормышың, сәне көттем, бән йазайым, сәңа һич йуқ бүләгем [Каргалый, 1988, б. 93]; көләрмен мин, бәнем бәхтем, сезләргә сүзем йуқ [Каргалый, 1988, б. 94]; онытма сән, қызықма сән [Каргалый, 1988, б. 97]; анларға [Каргалый, 1988, б. 104] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, тасвирлау, нигездә, *бән, сән*, ягъни сөйләүче, язучы белән тыңлаучы, укучы мөнәсәбәтендә алып барыла.

XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы татар поэзиясендә зат алмашлыкларын куллануда традиция дәвам ителә, шуның белән бергә, татар укучысына дип язылган әсәрләрдә кыпчак-татар сөйләмә телендәге формаларның ешрак кабатлануы күзәтелә.

Гали Чокрыйның тезмә әсәрләрендә: Лавзы датлы, холқы йатлы бер кәримә ирде ул [Гомәров, 2006, б. 116]; ул да былбыл булды анда, йар улыбдыр анлара [Гомәров, 2006, б. 117] һ.б.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә: мәйданда ул чықарды, бездән чықты, фанусны қабызған ул, сары майны тамызған ул [Акмулла1892, б. 2]; үтә алмайлар эзендән басыб аның, бара алмадым қашына аның, сүзенә артықча мән ғашыйқ аның [Акмулла, 1892, б. 3]; бездән дә фәиз бабы бикләгән йуқ [Акмулла, 1892, б. 4]; сезгә үтенәм сәлам йазып, бу сәбәбдән сезләргә сәлам йазам, килеп йатыр сезнең азан [Акмулла, 1892, б. 6] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, өченче зат берлек сандагы алмашлыгының еш кабатлануы, беренче һәм икенче зат алмашлыкларының күплеге төрле килеш кушымчалары белән файдаланыла.

Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә кулланыла торган алмашлыкларны «Г. Тукай. Шигърият теле» дигән хезмәткә нигезләнеп аңлату, аларның кабатлану ешлыгын төгәл итеп күрергә мөмкинлек бирә.

*Бән* алмашлыгы 48 мәртәбә, *бәндә* – 6, *бәнем* – 14, *бәни* – 13, *бәнчә* – 6, бәңа – 6 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 129–131]: У бер йаķны тотубән, бән дә – бер йаķ, Ķуйып киттем аның (вәҗғына) аwыруына тирйаķ [Тукай, 1985, б. 52]; Тотың мәғзур бәни, атам: бән алмам [Тукай, 1985, б. 62]; Ит бәни нәздеңдә үлмәклә сәғәдәт наили [Тукай, 1985, б. 100]; Бәңа: «Җанашым, исәнме?» – димәзсә [Тукай, 1985, б. 96]; Җаным ул, фазлит бәңа сән, улма җани җаныма [Тукай, 1985, б. 100]; Ишан хәзрәт билет бирсә бәңа гәр [Тукай, 1985, б. 96] һ.б.

*Мән* алмашлыгы 6 мәртәбә кабатлана, *бән* алмашлыгы белән чиратлашканда гына беренче зат берлек сандагы зат алмашлыгын белдерә: Санки ғыйшķың – бер кәлисә, бән аның накусием, Икләрем аһваһ идеб, мән насыйри, мән маили [Тукай, 1985, б. 100]. Бер очракта *җәнабе* сүзе белән бергә, билгеле бер затны аңлата: Вирер дәрмани дә, шайәт, җәнабе мән ләһелфәрман [Тукай, 1985, б. 70]. Дүрт очракта, билгесезлек төсмерендәге *бер* саны белән бергә, бер кеше мәгънәсендә кулланыла: Татлы ирнең үпсә бер мән, кәүсәреңне нишләсен [Тукай, 1985, б. 246]; Бер мән йаңа ғына туған айуны күрсә [Тукай, 1985, 2, б. 47]; Ничектер табыла дөнйада бер мән [Тукай, 1985, 2, б. 140].

*Мин* – 401, *миндә* – 5, *мине* – 42, *минеке* – 1, *минем* – 91, *минемчә* – 2, *мин-минлектән* – 1, *миннән* – 25, *минчә* – 1, *миңа* – 56 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, 2, б. 29-40]: Мин сезләргә бер сүз сөйлим [Тукай, 1985, б. 42]; мин алардан киммени, Мин дә сөйәмен кийемне бик кенә, Ник миңа да алмыйсың син, ник кенә [Тукай, 1985, б. 75] һ.б.

*Без* алмашлыгы – 147, *безә* – 5, *безгә* – 39, *бездә* – 35, *бездән* – 10, *безез* – 2, *безем* – 11, *бези* – 7, *безим* – 1, *безләр* – 2, *безләрә* – 1, *безләрдә* – 2, *безләри* – 1, *безне* – 39, *безнең* – 73, *безнеңлә* – 2, *безнеңчә* – 3, *безчә* – 1мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 135–140]: Мәғәриф мәйданында без, татарлар уйнаталым ат [Тукай, 1985, б. 24]; без дә инсан [Тукай, 1985, б. 46]; йазмасынлар безне [Тукай, 1985, б. 24]; Безез әсхабе, әүләде бу ғасры мәғрифәт ғасрың [Тукай, 1985, б. 25]; безнең ķанны бик күп имде [Тукай, 1985, б. 42]; бездә күзе ачыķ кешеләр дә бардыр [Тукай, 1985, б. 43] һ.б.

*Сән* алмашлыгы – 29, *сәнең* – 19, *сәнгә* – 1, *сәңа* – 16, *сәне* – 1, *сәни* – 1, *сәндин* – 4 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 114–116]: Өмидсең сән бу милләткә һәр эштә [Тукай, 1985, б. 50]; Сөйәрмен мин

сәне дә бик сөйәрмен [Тукай, 1985, б. 105]; Сәнгә хезмәтдер мәрамем йазмадан журналымы [Тукай, 1985, б. 312] һ.б.

*Син* алмашлыгы – 336, *синдә* – 6, *синдәй* – 1, *синдиләрне* – 1, *сине* – 49, *синең* – 62, *синеңчә* – 3, *синеңчөн* – 1, *синнән* – 14, *синсең* – 1, *сиңа* – 65 [Тукай, 2009, б. 123–132]: син үзең дә йалкау [Тукай, 1985, б. 31]; синдә мал беткәнне [Тукай, 1985, б. 32] һ.б.

*Сез* алмашлыгы – 79, *сезә* – 3, *сезгә* – 28, *сездә* – 2, *сездәй* – 2, *сездән* – 7, *сездиләргә* – 1, *сезең* – 5, *сези* – 7, *сезиң* – 1, *сезләргә* – 1, *сезләри* – 1, *сезләрне* – 2, *сезне* – 9, *сезнең* – 13, *сезсеңез* – 14, *сезчә* – 2 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 118–120]: сезнең хәрир мәндилеңез [Тукай, 1985, б. 27]; сезгә wафадыр [Тукай, 1985, б. 28]; Қызғанамын сезләрне [Тукай, 1985, б. 44] һ.б.

*У* алмашлыгы 7 мәртәбә кабатлана [Тукай, 2009, б. 223], шулардан: а) *бән* алмашлыгы белән чиратлашканда: У бер йақны тотубән, бән дә – бер йақ [Тукай, 1985, б. 52] һәм ә) эш башкаручының өченче зат икәнлеген аңлатканда: Бу хезмәтчөн азад улды у цензур нам әсарәтдән [Тукай, 1985, б. 320]. Калган 5 очракта күрсәтү алмашлыгы буларак: Тағы туқтар, тағы атлар у мискин, У мискини беләнчә қальбе мәҗрүх [Тукай, 1985, б. 51]; У гүзәл ғыйшқында әшғар сөйләмәкне халисән [Тукай, 1985, б. 58]; у динне башчылар бақсын [Тукай, 1985, б. 60]; Нә шағирдер у кем әшғар аңа мәүләдән ихсандыр [Тукай, 1985, б. 70]. Димәк, *у* алмашлыгы күрсәтү төшенчәсен белдерү вазифасы белән ешрак кабатлана.

*Ул* алмашлыгы Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә зат һәм күрсәтү алмашлыгы буларак 509 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, б. 231]. Зат алмашлыгы буларак: Тишек пима, тишек бишмәт илән ул, Буранлы көндә тотмыш мәктәбә юл [Тукай, 1985, б. 51]; Ышанмаңыз, бабай Сәйдәш надан ул, Түгел надан ғына – анларға хан ул [Тукай, 1985, б. 97]; Инде ул китте назад Аллаһ дигел, бәдәвам [Тукай, 1985, б. 109] һ.б.

Күрсәтү алмашлыгы буларак: Кәлде форсат ул кафәсләрне дә вәйран итмәйә [Тукай, 1985, б. 64]; Ул ишанлар милләтә дошман икәндер, белмәдем [Тукай, 1985, б. 66]; Ул кибетләр, мин сиңайтим, ул хисапсыз маллары, ... Ул тройка атлары, ул бик матур фәйтуннары, қайда ул төлке толыплар, қайда, ай-һай, туннары [Тукай, 1985, б. 145] һ.б.

Күрсәтү-ишарәләү зат яки әйберләр (ул, бу, шул, шушы, теге һ.б.), сыйфатлар (андый, мондый, шундый, тегенди һ.б.), рәвешләр (алай, болай, тегеләй, шулай, монда, мондый, ары, бире һ.б.), саннар (шул-

кадәр, шулчаклы һ.б.) өчен кулланылганга, күрсәтү алмашлыклары, зат алмашлыкларына караганда, сан ягыннан күбрәк очрый [Татар грамматикасы, 2002, т. II, б. 312–313; Хисамова, 2006, б. 148]. Өйрәнелә торган язма истәлекләрдә дә, нигездә, шул ук алмашлыклар файдаланыла, архаик формалар да дәвам ителә.

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә: ул кәримәи ниса, бу илә мәхкәм дотмақың, ул ирәнләр таҗы ул дәмдә, ул шәйхә, сим у дөрр ирмәс, ошбу хин, ул кәримә, боны, бу җәһәтдин, ошбу сүзләре, ошбу дөнйа хәсрәте [Каргалый, 1889, б. 2]; ул ләгыйн, шул җәһәтдән, ул тарафдан, ул капудан, бу сәбәбдин, хөббе дөнйа уламы мондыйун зийад, ул хәйрелбәшәр, ул дәм, мондыйун отры улачақ [Каргалый, 1889, б. 3]; вақыйф улыб боңа (بونكا), ул дин сәрвәре, болар, бу эшдә, бунларның шаинында айат иңдерүб ул Хәбибең өммәте, шуйлә мөшфиқ ирде ул шаһе гәзин [Каргалый, 1889, б. 4]; ошбу қаума, ошбу шәраб, ошбу тәғәм, ошбу бәлаи, ул кауме заль, ул рәсулуллә [Каргалый, 1889, б. 9]; بونلار ه – бунлара [Каргалый, 1889, б. 10], بونلار ه – бунлара, بونلار – бунлар, بونلارنك – бунларның, بونلارنك – бунларның [Каргалый, 1889, б. 11] һ.б.

[м] тартыгының язуда чагылышы вариант буларак кабул ителә: وندينмондин: حبدنيا اولامس موندين زياد – хөббе дөнйа уламы мондин зийад, موندين اوترو اولاچق بيله عتاب – мондин отры улачақ билә ғыйтаб [Каргалый, 1889, б. 3] һ.б.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыль адәб» җыентыгында: шуларга кем һидайәт итдең Илаһем, Ғазаб қылмай уларға қылдың инғам, шу йулны эстәйүрермез сән Ходайдан, бу дөнйа сәвеқыйда Иблис дәләл улуб итмеш бәңа чуқ мәкер илә ал [Салихов, 1856, б. 3]; бу дәм фәһем әйләдем, у йирдә бер нәһнең вар ағызын ачмыш, булары җәмғ идеб бер йирдә тотдым, у дәм йотды ул қалды нәбуд, шу дәм лә [Салихов, 1856, б. 4]; буларға нидәйем бән ғасый, бу кәз қалдым [Салихов, 1856, б. 8] һ.б.

Ш. Зәкинең «И дәрига...» дип башланган шигырендә: бер нәзар кылгыл бу үлмеш күңлемә, ошбу нәфсем афәтендән [Зәки, 2002, б. 40]. «Бән Ходаның...» дип башланган шигырендә: ул бер Тәңрейә йалwарасы, мөдам артыр бу күңлем йарасы, ошбу қайғы атәше ки [Зәки, 2002, б. 32]; Гәр ғыйнайәт қылмаса ул Шаһ бу ғасый бәндәгә, Хасыйл улыр аңа, Чуқ гөнаһ итдем бән ул Мәғбудемә бу дөнйада, ошбу бәндәнең әммарасы, бу ләғийнгә Сам-у-Рөстәм һиммәтен күстәрәсе, шул гадуның йөрәген қубарасы [Зәки, 2002, б. 33] һ.б.

Г. Кандалыйның шигырь һәм поэмаларында күрсәтү алмашлыкларының кулланылышында традиция дәвам ителә: бу асыл қошны, бу қайгулар [Кандалый, 1988, б. 73]; бу илләрдә [Кандалый, 1988, 75], бу хәсрәтләрне [Кандалый, 1988, б. 77]; бу шартлар берлә, моны идән кеше [Кандалый, 1988, б. 87] һ.б.

Г. Чокрый әсәрләрендә: ошбу йиргә бер нигяр, мәғәше андадыр [Гомәров, 2006, б. 116]; шул анамның раузасына, шул мәзарда улды йар, мисле ошбу мәғсумән [Гомәров, 2006, б. 117] һ.б.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә: бу дийарда бездән чықты [Акмулла, 1892, б. 2]; шул сәбәбдән, ул заман китап қайда бу замандай [Акмулла, 1892, б. 3]; шул сәбәбдән [Акмулла, 1892, б. 4] һ.б.

Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә: Иштә бу журнал ирер кәндиленез [Тукай, 1985, б. 27]; «Тәрҗеман» бу милләтең, Дәрденә улсын тәрҗеман [Тукай, 1985, б. 35]; Буңа бағлы дорыр бәхт вә сәғәдәт [Тукай, 1985, б. 36]; әлендә бунларың, будыр шатлық вирән дәрдле қолубә [Тукай, 1985, б. 37]; ушбу милләт йыртыгының җөйен җөйлим [Тукай, 1985, б. 42]; Қайчанға чақлы татар, ушбу уйқуда йатар [Тукай, 1985, б. 45]; бөйлә һиммәт, Измәсен безне җәһаләт бөйлә Алла ғыйшқына [Тукай, 1985, б. 46]; Шул бақалар йарға чыгып бақылдаша [Тукай, 1985, б. 55]; Нә сәбәбле кәлди безгә бөйлә бер бәхте сийаһ? [Тукай, 1985, б. 56]; Иштә йаздым шиғреми күздән ақан қанымла бән [Тукай, 1985, б. 58] һ.б.

Ераклык һәм якынлык төшенчәсен белдерә торган *әнә, менә* алмашлыклары парланып, тасвирый чагыштыру чарасы буларак кулланыла: Әнә чүлмәк: аңар қатық тутырған, Менә хәлфә: башы мантыйқ тутырған, Әнә қарға: мәчет өстенә қунған, Менә шәкерт: указлы мулла булған [Тукай, 1985, 2, б. 49] һ.б.

Сорау алмашлыклары, күрсәтү алмашлыклары кебек үк, төрле сүз төркемнәре белән мөнәсәбәттә була. *Кем, ни, нәрсә* алмашлыклары исемнәрне алыштырып килә алалар һәм алар кебек берлек-күплек, килеш белән төрләнәләр. *Нинди, кай, кайсы* алмашлыклары – сыйфатлар; *ничә, ничәнче, никадәр, ничаклы* – саннар; *ничек, кайда, каян, кая, кайчан* – рәвешләр; *нишләү, ни хәл итү* – фигыльләр белән мөнәсәбәттәш, шул сүз төркемнәренең грамматик билгеләренә ия булалар [Татар грамматикасы, 2002, б. 313–314]. Сорау алмашлыклары тарихи яктан караганда, *кем, кай, нә//ни* кебек өч төрле тамырдан барлыкка килгән [Хисамова, 2006, б. 149–151].

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә нә-/ни- тамыры нигезендә ясалган төрле сүз төркеме белән мөнәсәбәттәш алмашлыклар файдаланыла:

а) сан алмашлыгы: нәчәләр мәнкүб [Каргалый, 1889, б. 2]; нәчә мәғнәдә, нәчә күрә күземез, нәчә көнләр ач улубән [Каргалый, 1889, б. 3]; нәчә дөрлү вireб тәзиин, нәчә данайы даминә грифтар әйләйәндер бу, нәчә ғалимләрең, нәчә заһидларың [Каргалый, 1889, б. 5] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, «Кыйссел-әнбия» әсәре өчен яңа булып санала торган *нәчә* формасы еш кабатлана [Исхакова, 2005, б. 86–90];

ә) фигыль алмашлыгы: нула (шә ула) ки замм әйләсәң, нә ула йәд әйләрсәң Аллаһ исемене [Каргалый, 1889, б. 2]; сәғләбия нәтде (нә итде) дөнйа хәсрәте, нәйләде (нә әйләде) Қарунны дөнйа дәүләте [Каргалый, 1889, б. 2]; нидәлем (нә идәлем), нә әйләрсәң әмер [Каргалый, 1889, б. 4] һ.б.;

б) рәвеш алмашлыгы: нәтә фәһем әйләмәдең, ғали нәсәб? [Каргалый, 1889, б. 2]; нә хәдде вар [Каргалый, 1889, б. 6]; нә кадәр үстекчә ул вәлад сәғир, нәтә Һәмруд ғәләме нар әйләде [Каргалый, 1889, б. 8],

*Қай-//қан-* тамыры нигезендә ясалган алмашлыклар: қанда қалды кем аңа улмак рәшад, қаны шәфқәтлә дийәнәтдән әсәр? [Каргалый, 1889, б. 3]; қаны шәфқәт, қаны бездә шәрғ-дин, қанғысыйлә хөкем идәр йәрен Хода [Каргалый, 1889, б. 4]; теләр ирсәң қанда кит [Каргалый, 1889, б. 94]; қанда қалды [Каргалый, 2002, б. 98]; қандан теләрсә, керерәм [Каргалый, 2002, б. 101] һ.б.

*Кем* тамыры нигезендә ясалган алмашлыклар: кеми ағлатмады, кемдән дорыр бәңа бу халәт [Каргалый, 1889, б. 6]; кем әйләйә безне зәбун, йә кемнең вардыр әзайа қодрәте [Каргалый, 1889, б. 10] һ.б.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыль адәб» җыентыгында: Тәндә җаным ничә көн миһман икәндер, белмәдем [Татар әдәбияты, 1957, б. 52]; нитә тәнбия итмәдеңез, и қарендәшләр, бәни [Татар әдәбияты, 1957, б. 53]; Күреп қазый бу хәле сурды анда, Нә улды ике күзең кәтде қанда, үзе китде ки, белмәм қанда варды [Татар әдәбияты, 1957, б. 55]; нә йирдә қуйсалар, анда сөкүт ит [Татар әдәбияты, 1957, б. 60]; нә кем ғаҗизне күрсәң, әйләгел яр [Татар әдәбияты, 1957, б. 61] һ.б.

Ш. Зәкинең шигырьләрендә: Нитәем кем заил улмаз күңлемен бимарасы..., Нитә биргәймән җаwабы, хәзрәтенә варасы, Нә ғыйбадәт, нә итағәт, ваһ, нәчә йөз қарасы [Зәки, 2002, б. 33]; Нә хасыйл ула бәңа ялғызымдан? [Зәки, 2002, б. 34]; Қаны шул ир кем, күзе ачық [Зәки, 2002, б. 35]; Қайу йирдә ойырсам [Зәки, 2002, б. 36]; Ничә ел бу

хәрарәт ғәләмендә, нәчә сәркәшләрен муйныңы борды, нәчәне қылды йир қуйнында мәсҗүн [Зәки, 2002, б. 37]; аңламазсән ниндәйен сүз рәмзене [Зәки, 2002, б. 38] һ.б.

Г. Кандалыйның шигырь һәм поэмаларында: нәчә йыллар ғомер сөрдем [Кандалый, 1988, б. 74]; қайа булсам [Кандалый, 1988, б. 76]; Нәчә йимешләрең үсде? Нәчә йафрақларың дөшде? [Кандалый, 1988, б. 89]; ничек итим икән сабыр [Кандалый, 1988, б. 91]; бу тәқдир дигәнең нидер? [Кандалый, 1988, б. 92]; қайчан булғай чырағының зыйасы? [Кандалый, 1988, б. 95]; қайа китдең болай, хәзрәт [Кандалый, 1988, б. 97]; нә дөнйасы, нәдер динлек? [Кандалый, 1988, б.102]; кем илткәй бу сәламемне [Кандалый, 1988, б. 197]; нәчек барыйм, нәчек күрим [Кандалый, 1988, б. 117]; ниндәй булыр бара-бара [Кандалый, 1988, б. 138]; сәне қандин күрәрмен [Кандалый, 1988, б. 168]; нитәен бу бәлане [Кандалый, 1988, б. 172]; мондан йахшысы қаный? [Кандалый, 1988, б. 175–177] һ.б.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә: дөррәсендән қанча бала сөткә туйып [Акмулла, 1892, б. 2]; қайда бер тәхқыйқ күрсәм қуанамын [Акмулла, 2001, б. 12]; қайда мулла бар дисә [Акмулла, 1892, б. 4]; кемнең хәле беленер мөбһәм йатса [Акмулла, 2001, б. 14]; қуәтең қанча икән [Акмулла, 1892, б. 7]; Қайсысындан күренде мондый бәйан [Акмулла, 2001, б. 22]; Берәүне йаманларға қандай оста [Акмулла, 1892, б. 10] һ.б.

Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә: Кем идең, кем булдың? [Тукай, 1985, б. 31]; Кем қапамышдыр бези? [Тукай, 1985, б. 64]; Бән йығламай, кем йығласын [Тукай1985, б. 89–90]; Нә дәүләт милләтә, нә бәхет вә талиғ [Тукай, 1985, б. 34]; Шөруғ итсә, нәләр йапмас бу милләт [Тукай, 1985, б. 38]; Нә сәбәбле кәлди безгә бөйлә бер бәхте сийаһ? [Тукай, 1985, б. 56]; Қайда китте цензуралык [Тукай, 1985, б. 40] һ.б.

Үзенә караган (кайтым) алмашлыгы. Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә: кәндүйә дақған мөхибләр намыны [Каргалый, 1889, б. 3]; кәндүләре ач улуб, кәндүсе мәдех итде [Каргалый, 1889, б. 4]; үзине дөхтәр дүшизә кеби күстәреб, дөнйа, нәү идеб кәнден, кәндүсенә [Каргалый, 1889, б. 5]; кәнде сачемлә [Каргалый, 1889, б. 6]; үзеңдин ғайреңә мохтаҗын Илаһ [Каргалый, 1889, б. 7]; кәндүсенә тәғате қылды таләб [Каргалый, 1889, б. 9] һ.б.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыль адәб» җыентыгында: үзем мөфлис [Салихов, 1856, б. 8]; кәнде нәфсем [Татар әдәбияты, 1957, б. 53]; үзе кәтде ки [Татар әдәбияты, 1957, б. 55]; белмәз үзене, үзе

қазыйға варыр [Татар әдәбияты, 1957, б. 56]4 гәр анлар үзләре чыкса сәфәргә [Татар әдәбияты, 1957, б. 58] һ.б.

Ш. Зәкинең шигырьләрендә: үзене пәнһан итәр [Зәки, 2002, б. 31]; Кәндеме бу әһле дөнйа арасындан [Зәки, 2002, б. 32]; Бәңа нәфғ улмайа һич кәнд-үземдән [Зәки, 2002, б. 33]; кәнд-үзен тәүфыйқ һидәйәт берлә әстар әйләде, үзене шәйәстәи дәргяһе дидар әйләде [Зәки, 2002, б. 36], кәндеңә золым әйләмәшесән [Зәки, 2002, б. 39] һ.б.

Г. Кандалый иҗатында: даим булдым үзем гъөрйан, һаман тордым үзем кышда [Кандалый, 1988, б. 74]; үз белгәнемне итәрмен [Кандалый, 1988, б. 75]; сүзе монда, үзе юк [Кандалый, 1988, б. 94]; зикер әйтик үзеңезгә [Кандалый, 1988, б. 95]; Үзең сақланмасаң, сәне кемләр сақлар, Үзең саклансаң, сәне Хода сақлар [Кандалый, 1988, б. 113]; Йаныңнан йебәрмәсәң үзең сөреп [Кандалый, 1988, б. 114]; белерсең кәндүзең ир дип [Кандалый, 1988, б. 264] һ.б.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә: үземнең ноқсаныма иқрарым бар [Акмулла, 1892, б. 4]; үзеңездән бер фазыйл була калса [Акмулла, 1892, б. 7] һ.б.

Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә: Кәнде хөснеңдән хәбәрсез бер гүзәл чуҗық кеби, Сези тәқдирә мәҗбүрем, дәгел кәнде хыйалымнан [Тукай, 1985, б. 85]; Һәп сәнең – қальбем, вә кәндем мөштәрайым, нәйләйем? [Тукай, 1985, б. 82]; Кәндемә мүнис идәндем қальбе гирйанымла бән [Тукай, 1985, б. 58]; Хурлыққа салма кәндү кәндүзең [Тукай, 1985, б. 322]; Үз-үзеңә қара [Тукай, 1985, б. 31]; үзеңдә йалқаулық [Тукай, 1985, б. 32]; Үземә бақмаңыз – үзем начармын [Тукай, 1985, б. 48]; Үзеңне әгнәдән йарлы күрмә [Тукай, 1985, б. 52]; Үз-үзеннән разый булыр [Тукай, 1985, б. 180] һ.б.

Билгеләү алмашлыклары. Сорау алмашлыкларына, вакыт, урын һ.б. мәгънәләрне белдерә торган абстракт исемнәргә *һәр* алмашлыгы кушылып ясала, *бар* хәбәрлек сүзенең һәм *бөтен* сыйфатының мәгънәләре үзгәреп ясала. Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә: һәр кеше [Каргалый, 1889, б. 2]; вирделәр барын, ханә дулу җөмләмез һәм ачмыз [Каргалый, 1889, б. 4]; җөмлә дин қардәшләремезлә бәһәм [Каргалый, 1889, б. 5]; әлендә ғаҗиз улды җөмлә көффар [Каргалый, 1889, б. 5]; һәргиз вирмәйеб бер дәм әмани, җәмиғы қаинәтнең әфзале [Каргалый, 1889, б. 6]; һәр ан ирер шөкрана, һәргиз улмады бу фазыл әғзәм, җәмигы өммәтә безләрдән әқдәм [Каргалый, 1889, б. 7]; идә Хақ рәхмәтене һәрберенә [Каргалый, 1889, б. 7]; һәрнә деләрсә, қылыр [Каргалый, 1889, б. 8]; һәрберенең

хадиме [Каргалый, 1889, б. 10]; әйләделәр ҡамусын [Каргалый, 1889, б. 10]; ҡамусын ҡылды шүр [Каргалый, 1889, б. 11] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, хәзерге әдәби телдә кулланыла торган алмашлыклар белән бергә *һәр гиз, һәр ан, һәр дәм, җөмлә, камус* кебек алынмалар да актив файдаланыла.

Һ. Салиховның әсәрләрендә: җөмлә ҡачмыш [Салихов, 1856, б. 4]; барысы хосран икәндер, белмәдем, җөмләсе вәйран икәндер, [Татар әдәбияты, 1957, б. 52]; көлле нәфсин [Татар әдәбияты, 1957, б. 53]; бәһәр нәүгы боларның золымыдыр фаш [Татар әдәбияты, 1957, б. 60] һ.б.

Ш. Зәкинең шигырьләрендә: Аңа һәр кем бәндә булса [Зәки, 2002, б. 30]; һәргиз икселмәс, мөдам артыр бу күңелем йарасы [Зәки, 2002, б. 32]; Солха килмәз, һәргиз ошбу бәндәнең әммарасы, Туғмады һәргиз анадан бән кеби бичара кол, ҡаму ғыйсйан тәксыйремне ғафу ит [Зәки, 2002, б. 33]; һәркем күзендән түксә йәш [б. 36],

Г. Кандалый әсәрләрендә: ҡәму ғәмләр китәр андин [Кандалый, 1988, б. 87]; Илаһи, барча ғаләмне, Йаратдың ҡодрәтең берлән [Кандалый, 1988, б. 88]; ки һәркем исми йад итсә, вирә маҡсудины Алла [Кандалый, 1988, б. 90]; даны тоткан бөтен илне [Кандалый, 1988, б. 116]; табыла дөнйада һәрбер кирәкләр [Кандалый, 1988, б. 150]; фида улсын сәңа һәм җөмлә малым [Кандалый, 1988, б. 170] һ.б.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә: чәйгә һәркем су алғандай [Акмулла, 1892, б. 2]; һәр йирдә сәнәд илә сүзе баһир, һәр тарафҡа [Акмулла, 2001, б. 11]; һәркемгә хазз бирелгән ҡыйсмәт берлән [Акмулла, 1892, б. 4]; һәрҡачан тәвазզуғда бармы нәкыс? [Акмулла, 2001, б. 19]; керләсәң һәр нәрсәне [Акмулла, 2001, б. 20] һ.б.

Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә: Күрәм булган, буласы барча йахшы вә йаманнарны [Тукай, 1985, 2, б. 13]; Сезгә тәслим әйләмеш милләт бөтен әүраҡыны [Тукай, 1985, б. 84]; Бөтен сүзен, эшен синең ҡарышҡа [Тукай, 1985, б. 94]; Бөтен дөнйа, Ҡалды хәйран [Тукай, 1985, б. 122]; Җәмиғы ҡолларың [Тукай, 1985, б. 28]; Җәмиғы әҡрибәм [Тукай, 1985, 2, б. 13]; Бөйлә һиммәт безгә җөмлә сөннәт Алла ғыйшҡынға [Тукай, 1985, б. 46]; Бу йул илә йитешмеш җөмлә әшраф [Тукай, 1985, б. 51]; Ҡыйраәт әйләдем, әзбәрләдем бән җөмлә асәрең [Тукай, 1985, б. 70]; «Әлислах»ка йәрдәм итик һәммәмез дә [Тукай, 1985, б. 201]; Сачтылар алтын-көмешнең һәммәсен [Тукай, 1985, б. 269]; Һәр кимә үз дилилә тәфһим идәр, Һәр лөзүмле шәйләри тәкдим идәр,

Нурлана бу дөнйада һәр нә ки вар [Тукай, 1985, б. 27]; Һәр тарафқа нур сачәр, мәшһүр улыр [Тукай, 1985, б. 34]; Ки һәрберсе безем әхwәлә ғаид [Тукай, 1985, б. 37]; Һәр милләтләр мақсудларын хасил итә [Тукай, 1985, б. 42]; Һәр көн үзгәрә заман [Тукай, 1985, б. 44]; Һәрбересе йәшәрешеп йафрақ йара, Һәр ағачта сандуғачлар сайрар имди [Тукай, 1985, б. 55]; Һәркемгә, һәрнәрсәгә, һәр туғрыда [Тукай, 1985, б. 160]; Инде һәркем күңленә шатлық тула [Тукай, 1985, б. 275]; Улың бу журнала һәп мөштәриләр [Тукай, 1985, б. 27]; ...И каләм, сәндин кәлүр һәп бәхтемез, иқбалемез [Тукай, 1985, б. 56] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, ерак гасырлардан традиция булып килә торган алмашлыкларны куллану дәвам иткән хәлдә, сан ягыннан халыкчан вариантның өстенлек ала баруы аңлашыла.

Билгесезлек алмашлыклары хәзерге әдәби телдә сорау алмашлыкларына *-дыр/-дер* һәм *әллә* кисәкчәсе ялганып ясала. Ә. Каргалый иҗатында: бөтен дөнйа бәнем булса, гамем бетмәс – нәдәндер бу? [Каргалый, 2002, б. 122] һ.б.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыль адәб» җыентыгында: анларый кемдер сәвисәр [Татар әдәбияты, 1957, б. 60] һ.б.

Г. Кандалый шигырьләрендә: Ғаҗәб ләтыйфәдер җисмең, Ки белми ничекдер исмең [Кандалый, 1988, б. 157]; Ки бәндәсән: ничекдер ул талиғә [Кандалый, 1988, б. 164]; сәнең исмең фәләнә [Кандалый, 1988, б. 170]; Ғыйшықлықдин берәүгә ут чақылса [Кандалый, 1988, б. 184]; ки исмең һәм фәлян булды [Кандалый, 1988, б. 186]; мөбәрәк исмеңез фәлән икәндер [Кандалый, 1988, б. 189]; Фәлән шәкерт фәлән атлы бу йарға [Кандалый, 1988, б. 195] һ.б.

Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә: Болар кемдер, буны йахшы белик без [Тукай, 1985, б. 48]; Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам басқан йоқы [Тукай, 1985, б. 158]; Нидәндер җаннарым бу қурқулардан бер дә сызланмый [Тукай, 1985, б. 93]; Ақчаны алғач, әби киткән нидәндер Әтнәгә [Тукай, 1985, б. 237]; Нидәндер анда мин шатлық, азатлықларны һич күрмим [Тукай, 1985, 2, б. 126] һ.б.

Г. Тукайның шигъри әсәрләрендә *әллә* кисәкчәсе 96 мәртәбә кулланыла [Тукай, 2009, б. 92–93]. Сорау алмашлыклары белән бергә килеп, билгесезлек алмашлыклары ясалу очраклары да еш кабатлана: Әллә нәрсә киңәшәләр [Тукай, 1985, б. 55]; Әллә қайдан фетнә чығарыр, табар [Тукай, 1985, б. 75]; Әллә нәрсәм йуқ кеби [Тукай, 1985, б. 158]; Йәмсез таwышлы әллә нәрсә қычқыра, қаршысында әллә нинди йат күрә, әллә нинди нәрсә бу [Тукай, 1985, 170] һ.б.

Юклык алмашлыгы сорау алмашлыкларына *һич, бер, һичбер* кисәкчәсе ярдәмендә ясала, *-да/-дә* кисәкчәсе белән көчәйтелә. Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә: әйләмәз асла (һичбер вакыт) [Каргалый, 1889, б. 4]; күрмәс иде вәзгыдан һичбер әләм [Каргалый, 1889, б. 8]; килмәде имана аслан һичбере [Каргалый, 1889, б. 10]; қалмады һич ниғмәт малдан нишан [Каргалый, 1889, б. 11] һ.б.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыль адәб» җыентыгында: нәзар һич итмәел сағ сулына [Татар әдәбияты, 1957, б. 54]; ғаса кеби ғомердә (һичкайчан, бер дә) күрмәсәң аш [Татар әдәбияты, 1957, б. 62] һ.б.

Ш. Зәки шигырьләрендә: Сөйләмә һич кемсәйә йахшы-йаман, Хәлеңә хәлдәш булынмаз бу заман [Зәки, 2002, б. 38]; һич кемә золым итмәдең [Зәки, 2002, б. 9] һ.б.

Г. Кандалый иҗатында: ғыйлем сахибе һичбер дә черемәс, үлсә дә, гүрдә [Кандалый, 1988, б. 71]; бу чәйдик һичбере йуқдыр [Кандалый, 1988, б. 84]; сиңа һич йуқ бүләгем [Кандалый, 1988, б. 93]; сәндин башқа һич кемсәгә бақмам имди [Кандалый, 1988, б. 110]; бу йомшау сәндин һич дә кәлмәз имди [Кандалый, 1988, б. 111]; Хатасыз һичкем булмас Хақдин үзгә [Кандалый, 1988, б. 114]; Ничек беркемне дә сөзмәй [Кандалый, 1988, б. 116]; бу дөнйада сәңа һичкем ошамый [Кандалый, 1988, б. 204] һ.б. Аңлашылганча, *һич* белән ясала торган юклык алмашлыгы эзлекле кулланыла.

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә: Бу чақда һичкем аңа тиң килмәйде, Бу йалар һичкемне аңа тиңәрмәйде [Акмулла, 2001, б. 21] һ.б.

Г. Тукайның шигъри әсәрендә: Азмағанны һичбер қәләм йазмас имди [Тукай, 1985, 81] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, өйрәнелә торган чорда язылган тезмә әсәрләрдә алмашлыкларның барлык төркемчәләренең дә кулланылуы, әмма төрле авторда төрле дәрәҗәдә файдаланылуы аңлашыла.

XIX гасырның икенче яртысыннан, XX гасыр башына кадәр иҗат ителгән сәнгатьле чәчмә әсәрләрдә алмашлыкларның ничек кулланылуына игътибар юнәлтәбез.

Сәнгатьле прозаны хикәяләүнең беренче төренә карый торган чәчмә кыйссаларда алмашлыклар.

Зат алмашлыклары. К. Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы»нда риваять китапларында язылган хикәятләр «Гаҗәм йортында Ханкыйун исемле бер олуг падишаһ бар иде», – дип башлана да, өченче зат

берлек сандагы алмашлыклар файдаланылып дәвам итеlә: Җиде иқлим аның қулы астында иде, шәһири йарлық вә солтанат анда бар иде, Хак Тәгалә хәзрәтләре аңа бер сөйекле вә мәхбүб уғыл бирде, аның күркәмлегенә вә җәмалына гашыйк иде [Насыйри, 1975, б. 221]; аның кебек адәм йуқ иде, аны күркәм сыйфатлары, вә аны ғомеремнең маясы дип белер иде [Насыйри, 1975, б. 222]. Персонажларның сөйләме итеп бирелә торган өзекләрдә, I зат алмашлыклары файдаланыла: синең талиғыңа қарадым, минем wасыйәтемне тотмақ кирәксең, син ни бойырырсың фәрман синеңдер диде [Насыйри, 1975, б. 222]; сиңа ни булды, әгәр син минем белән күңел бер итеп, минем қулымдадыр, уғлан аңа дәхи җаwап бирмәде [Насыйри, 1975, б. 223] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: Без килдек Әбүгалисина вә Әбелхарис хикәятенә [Насыйри, 1898, б. 9]; безгә бәйан қылып, шөбһәдән безне чығара күр, безләрне хәйран қылды, безгә дә ул һөнәрләрен күрсәтеп, безгә моны бәйан вә ғайан қыла күр [Насыйри, 1898, б. 216] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы» да: мән фәқыйр сәр вә пөртәқсыйр Ғабделғалләм Фәизхан уғлы, аларның һәр кайусында, ул телне безнең халқымызға аңлаwы мөшкел булғанлықдан [Фәизхан, 1896, б. 2]; сиңа бер изге бала ихсан итәр, аның исемене Сәғыйд қуйарсың, мән сәндән шундай уғыл теләдем ки, ул изге вә ғақыллы вә қамил булғай иде диб вә мәнем қартлығым wақытында ул кәсеб итеб мән рәхәттә булсам иде [Фәизхан, 1896, б. 3] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Бүз йегет» әсәрендә: төшдә күрдең сән бәни, сабыр иткел сән әле, без хәзермез, без илүңә барғанча [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 2]; йекет килсә, мәндин сөйенче сораб, алар көнләрдә бер көн йатыб йоқламыш ирде, ғафилме сән җан җегет, мән йулыңда интизар [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 3]. Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: һәркем мәңа мең алтын садақа ихсан қылса, И дәрвиш, сән кем сән, мәңа хәбәр биргел, мән румаллар остазы мән [Уразаев-Кормаши, 1879, б. 3]; мән сәнең қарендәшең мән, сер илән сердәшем син, йулым илән йулдашым син, син мәңа қарендәш син [Уразаев-Кормаши, 1879, б. 6] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, I зат берлек сан алмашлыгының рәттән кыпчак варианты кулланыла. II зат берлек сан алмашлыгының да сузык авазы күрсәтелеп языла.

Күрсәтү алмашлыклары. «Кырык вәзир»дә: бу сүзне, бу көн, бу қазаны, чара шулдыр, бу уғлан, [Насыйри, 1975, б. 222]; бу эшкә, ул уғры қулындан [Насыйри, 1975, б. 224]; ул кичә, бу сүзне [Насыйри,

1975, б. 225]; бу сүзләр, ул сурәтләрне, ул бүлмәнең, шул сыйфатта, бу сурәтләр, [Насыйри, 1975, б. 226]; шул бикнең [Насыйри, 1975, б. 227]. һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: ошбу китапны, бу қыйссаны, ул китапны, [Насыйри, 1898, б. 2]; шундайын кешеләр бар [Насыйри, 1898, б. 208]; ошбу Әбуғалисина қыйссасын [Насыйри, 1898, б. 208]; моның зирәклеге [Насыйри, 1898, б. 209]; шул күлгә чумды, болар эзли торсынлар, болай мәғнәсез хәрәкәтнең [Насыйри, 1898, б. 214]; шуның кебек йегетләрем бар, болар бер туғма қарендәшләрме [Насыйри, 1898, б. 216]; шундайын җәмал ийәсе бер қыз итде ки, ошбу қыздан [Насыйри, 1898, б. 218]; мондайын ғәҗәп wақыйғаны [Насыйри, 1898, б. 220] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда: ул пәйғәмбәремез, ошбу Тутыйнамә китабыны, ул телне, бу китабда зикер қылынған, шул рәwешле [Фәизхан, 1896, б. 2]; ошбу шәһәрнең, ул қартның үгрәтүе буйынча, ул шәһәрдә ғалимләр вә ғилме нөҗүм белгүчеләр күб иде, ул мәҗлескә чақырыб [Фәизхан, 1896, б. 3] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Бүз йегет» әсәрендә: ул килмеш сурәт янында булмады, ул сурәтнең ғыйшқы қызға әсәр итде, шул йылғы, моның берлән [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 2–3]. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: шундағ риwайәт вә мондағ хикәйәт қылур, бу падишаһның, шул сәбәбдән һәрwақыт күңеленә бераз қайғу вә тарлык килер иде, бу фикер илә калды, шундайын дилкәшад бақча иде, шул заман, бу падишаһның [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 2]; ул кемсәнең күңелендә, бу қәдәр хәкимнәргә, бу дәрвишләр арасында, ошбу қәләмне тотыб, ул һәм ошбуның кеби уйлады [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 3]; чөн болар икешәр йәшләренә керделәр, болар шундайын ғақыллы вә фәрасәтле иделәр [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 5] һ.б.

Сорау алмашлыклары. «Кырык вәзир»дә: ничә һөнәре бар [Насыйри, 1974, б. 221]; ничә заман ғыйшқын күңелендә йәшереп, ни чара дип, ни уқыдың, ни йаздың [Насыйри, 1974, б. 222]; ничек үтерим дисәң [Насыйри, 1974, б. 224]; падишаһның ачуына нидән болай тиешле булды [Насыйри, 1974, б. 225]; болар ничек қоллық итсен? [Насыйри, 1974, б. 226]; қайсы мөселман тапса да [Насыйри, 1974, б. 231]; Бағдад тегүчеләре қайда қалды? [Насыйри, 1974, б. 232] һ.б. *Нинди* урынында *ничек* алмашлыгы файдаланыла: бу қыз ничек қыздыр [Насыйри, 1975, б. 241]; сез ничек кешеләрсез? [Насыйри, 1975, б. 245] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: ничә мәгърифәт ийәсе адәмләр белән күрешеб, Әбүғалисина хақында ничә ғәҗәйеп хикәйәтләр вә ғараип ривайәтләр ишетеп [Насыйри, 1898, б. 2]; бу мәғәрә ниндәйен мәғәрәдер? Вә анын ачылмағы ни кәйфийәттәдер? [Насыйри, 1974, б. 210]; ничә көн әwәрә булып [Насыйри, 1974, б. 214]; ниқәдәр һөнәр эстәсәңез [Насыйри, 1974, б. 216]; ни эшең вә ни мәслихәтең бардыр, ничә мәртәбә атасыннан сорадым [Насыйри, 1974, 217]; моннан қыз ничек ғаиб булды [Насыйри, 1974, б. 220] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда: ничә төрле файдалар алмышлардыр, аларның һәр қайусында ничә вә ничә гыйбрәләр хасил булыр [Фәизхан, 1896, б. 2]; қайда бер мөбарәк урын бар диб хәбәр алса [Фәизхан, 1896, б. 3]; бу нинди җенесдән булган Тутый икән? [Фәизхан, 1896, б. 4] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: қайсы вилайәтдә вә қайсы шәһәрдә бер хәким хазиқ вә табиб қамил ишетсә, мәхлүк ни кылсын [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 2]; И дәрвиш, кем син? Бу китапларың нидер? Ғыйлемлекнең теләwе буенча ниләр заһир булыр? [Татар әдәбияты, 1957, б. 288]; Бу ни дигән хурлықтыр, бу ни дигән зурлықтыр? [Татар әдәбияты, 1957, б. 297] һ.б.

Кайтым алмашлыклары. «Кырык вәзир»дә: үзенең сарайына китерде [Насыйри, 1975, б. 222]; үзенең хәрәменә [Насыйри, 1975, б. 224]; үз башыңны қоткарырға [Насыйри, 1975, б. 225]; үзең хисап ит [Насыйри, 1975, б. 226] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: үзендән сөйләгәнлегенә күрә, үземнең белгәнем [Насыйри, 1974, б. 207]; үзендәАллаһе Тәғәлә биргән ни қәдәр ғыйлем вә мәғрифәт, үзенең итағәтенә өндәде [Насыйри, 1974, б. 210]; қайсысы үзләренекедер, үзенә вәзир итеп күп ғыйззәт вә хөрмәтләр күрсәтте [Насыйри, 1974, б. 211]; үзенең сараена қайтды [Насыйри, 1974, б. 215]; үзен бу мәҗлестә күреп [Насыйри, 1974, б. 218]; үзенең хилвәт хөҗрәсеннән ғаиб булып [Насыйри, 1974, б. 220]; үзенең тәдбиренә мәшғүл булды, үзен бер күлгә ташлап [Насыйри, 1974, б. 225] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда: бер солтан ғосмани хәзрәтләре ошбу Тутыйнамә китабыны тәркиб ғылырға үзенең бер ғалим вә дана кешесенә табшырды, үз татар телемезгә, кәнд төрки теленә, үз хәлләренчә қалдырылды [Фәизхан, 1896, б. 2]; малының хисабыны үзе һәм белмәс иде, үз-үзен сақласын диб, Алла Тәгалә үзенең фазыйл вә кәрәмендән [Фәизхан, 1896, б. 3]; сән үзеңдәге мең алтынға сөнбелә ал [Фәизхан, 1896, б. 5] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: Аллаһе Тәгәлә үзе бирмәсә [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 2]; Зөһрә үзенең гүзәллек бөстаныннан [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 6]; кәнделәрене назға чигеп [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 7] һ.б.

Билгеләү алмашлыклары. «Кырык вәзир»дә: һәркем аның җәмалына караса [Насыйри, 1975, б. 221]; атаңның һәрни нәрсәсе бар булса [Насыйри, 1975, б. 223]; қырық вәзирнең барчасы, барча wакыйғаны, ул нәқышларға қарап барчасын сәйер итте [Насыйри, 1975, б. 225]; бөтен дөнйа қәдәр [Насыйри, 1975, б. 227]; барча оста тегүчеләр арасында [Насыйри, 1975, б. 232]; һәрқайсы күрергә килә башладылар [Насыйри, 1975, б. 232] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: һәр заман күңелемә килер иде [Насыйри, 1974, б. 207]; һәрбер шәһәрнең изгеләре вә ғалимләре белән танышып [Насыйри, 1974, б. 209]; җәмиғ мәхлүқат аның әмеренә мотыйғ булғач [Насыйри, 1974, б. 210]; узған-барған һәркем булса, җәмиғ китапларын күздән үткәреп [Насыйри, 1974, б. 211]; һәр тарафтан [Насыйри, 1974, б. 214]; һәрберсенә берәр дастымал сарып, һәммәсе айақ үзрә қалқып, һәммәсе аwазсыз, һәрбер күргән кеше, һәммәсе бер-беренә охшар, һәрқайсыннан [Насыйри, 1974, б. 215] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда: дөнйа йөзенең һәр падишаһлығына таралуб, һәммә дәрд әһелләре уқуб файдалансынлар өчен [Фәизхан, 1896, б. 2]; һәр қайда бер доғасы қабул булған кешене ишетсә, бөтен шәһәрне ақтарыб, барча дустларыны йыйыб [Фәизхан, 1896, б. 3]; җәмиғ ғомерне хатуның йанында үткәрмәк лаиқ имәсдер, дөнйада ни чақлы қабәхәт бозық эшләр бар һәммәсен қылур иде, бу хәлендән барча қарендәш ыруғлары ғәрләнешеб, мәзкүр сиксән изгеләрне һәммәсен йулдан чықарыб, бәһасе мең алтындыр һәркем алса, ғәҗәйеб ниғмәтләргә вә ничә мең дәүләтләргә ирешүр [Фәизхан, 1896, б. 4] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: бу падишаһның һәркайчан күңеленә қайғы вә тарлық килсә, һәркем мәңа мең алтын садака ихсан кылса [Татар әдәбияты, 1957, б. 287]; бөтен солтанатым бирсәм кирәктер [Татар әдәбияты, 1957, б. 288]; һәр икесе бала өчен нийәт қылмышдыр [Татар әдәбияты, 1957, б. 289]; киң дөнйа һәр икесенең башларына тар булды [Татар әдәбияты, 1957, б. 300] һ.б.

Билгесезлек алмашлыклары. «Кырык вәзир»дә: берничә көннәр үткәч, бер заманнан соң, берничәне өйрәтеп [Насыйри, 1975, б. 222];

бер заманнан соң [Насыйри, 1975, б. 224]. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: бәғзе адәмләр файдасындан мәхрүмнәрдер [Насыйри, 1974, б. 208]; олуғрақ шәкертләреннән бәғзесе әйтер иде [Насыйри, 1974, б. 209]; базарда берәүдән туқтатып сорадылар [Насыйри, 1974, б. 210]; бәғзеләре җен эше вә бәғзеләре дәхи китап қарап [Насыйри, 1974, б. 220] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: бәғзе җирләргә ташлар иде, бәғзе ғашыйқлар табып, бәғзе wақытта [Татар әдәбияты, 1957, б. 301] һ.б.

Юклык алмашлыклары. «Кырык вәзир»дә: атасына һич җаwап бирмәде [Насыйри, 1975, б. 223]4 һичбер сүз сөйләмисең, һичбер хәреф сүз сөйләмәде, һичбер хилафлык итмәсмен, һич сүз сөйләмәде [Насыйри, 1975, б. 223]; һичкем белмәс, һичбер сүз сөйләмәгәч [Насыйри, 1975, б. 224]; һичкем аның кебек тегүчелек ғыйлемендә остаз чықмады [Насыйри, 1975, б. 231]; һичбер кеше, һич сабырым қалмады [Насыйри, 1975, б. 241] һ.б.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда: wақытны асла буш уздырмаслар иде [Насыйри, 1974, б. 213]; һич берсеннән җаwап ишетмәде [Насыйри, 1974, б. 215]; һич гаҗәп йуқ диделәр [Насыйри, 1974, б. 221] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда: сүзләрдән һич нәрсә сөйләмәс [Фәизхан, 1896, б. 4]; һичкемгә белдергәнем йуқ иде, Хуҗа Сәғитдән башқаға һич сөнбелә қалмады [Фәизхан, 1896, б. 5] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: дөнйада һичнәрсәгә ихтыйаҗы йуқ иде, һичбер файда тапмағач [Татар әдәбияты, 1957, б. 287]; һичкемгә қарамый йазу йазар [Татар әдәбияты, 1957, б. 288]; мәғрифәтенә һич сүзем йуқдыр [Татар әдәбияты, 1957, б. 289]; бонларның мәхәббәтләрендә һич кимчелек йуқ иде [Татар әдәбияты, 1957, б. 295] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, кыйссаларда алмашлыкларның барлык төркемчәләренең дә файдаланылуы күзәтелә.

Сәнгатьле прозаны хикәяләүнең икенче төренә карый торган мәгърифәтчеләр иҗатында да аларның кулланылуы күренә.

Зат алмашлыклары. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: аның ысулы тәдрисе [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; бән улайым, сез улыңыз [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48]; ул атасыны һич йадына алмады [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 49]; сез йахшы қылдыңыз, ... бән чықмаз идем, бән хата қылдым, безем қағыйдә вә қануннарымыз, без кидәлем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50];

сезә аwыл қызы йақышмаз, сезә шәһәрле кирәк [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 52]; бездә мәҗлес улыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53] һ.б.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында: бән сәғәткә қарап, бәңа өч рублә на чай виреп [Бигиев, 1991, б. 222]; сезләрә дә, хөрмәтлү уқучыларым, Мусаның ниндәләйен адәм идекене белдерәм [Бигиев, 1991, б. 223]; сезне күрергә эстәйән адәмнең исеме [Бигиев, 1991, б. 224]; бездә нә хезмәтеңез вар, сездә зур хезмәтем йуқ [Бигиев, 1991, б. 224] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында: безем аwылдашларымыз, безем аwылдан, безем қәрйәмездә [Бигиев, 1991, б. 255]; сез бу егетне мәдрәсәйә [Бигиев, 1991, б. 258]; безем мәдрәсә имамы, мән үз тарафымдан [Бигиев, 1991, б. 258]; ул мәңа ... әйткән иде [Бигиев, 1991, б. 262]; мәнем хақымны [Бигиев, 1991, б. 263] һ.б.

Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» хикәясендә: мин синнән көлмимен, мин үземезнең мөселман қәрдәшләремезнең [Кәрими, 1996, б. 30]; менә аларның артыннан [Кәрими, 1996, б. 31]; сез булсағыз ни эшләр идегез [Кәрими, 1996, б. 31]; сезне белмим [Кәрими, 1996, б. 32]; безнең ақ җиләнле вә чапанлы кешеләр [Кәрими, 1996, б. 32]; минем бу исәбемнең туғры чықдығы беразға сезгә дә мәғлүм булыр [Кәрими, 1996, б. 32]; без сезнең динегезне белмибез [Кәрими, 1996, б. 33]; алар кинә сөйләшә қалдылар, мин дә торып киттем [Кәрими, 1996, б. 35]; бу да анлардан берсе булса кирәк [Кәрими, 1996, б. 38] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: без дә бу әсәремезне нәшер итмәк улдық [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 264]; бән Қазанға килдекем йылда, бәнем өчен, сәрбәстлек бу мәдрәсәдә бәңа вар иде, бәне мәнғы идәчәк кемсәнә йуқ иде, бәнем өчен бөтен дөнйа wатан, бәнем бер йалғызыма [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268] һ.б.

Күрсәтү алмашлыклары. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: бу ханәдә ... торырлар иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 45]; бу нумирә, ошбу нумир [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48]; шу йирдә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48, 49]; бу тап шул Хисаметдин менла, бу кеби кеше илә, буннан бөйлә йәш әфәнде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 49]; шәһәрә буннан қач чақрым улыр, ул шәһәрдә, бу масафирханә, бу нәзек бил вә җәмилә қыз [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50]; улсы йаман, бусы йаланчы, ул бересе хөрсез [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53]; у берессе тиҗарәттә wақыт кичермәктә иделәр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 57] һ.б.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында: ул қәдәрлесе мәғлүм түгел [Бигиев, 1991, б. 221]; бу хатын, бу мәқтүләнең, бу йирә, бу тарика, бу нумер ишегегене, бу үткән кичтә [Бигиев, 1991, б. 222] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында: шу мөскиратдан сақланыңыз [Бигиев, 1991, б. 256]; бу көндә йаздығымыз, бу көнә қәдәр өч ай wақыт кәчде [Бигиев, 1991, б. 257]; шу сәбәбдән [Бигиев, 1991, б. 257]; бу шәкердкә, ул мәдрәсә, шу мохтаҗ фәқирләрнең [Бигиев, 1991, б. 258]; шул йөзе қара [Бигиев, 1991, б. 264] һ.б.

Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» хикәясендә: бу адәмләр [Кәрими, 1996, б. 32]; мин бу тапларны [Кәрими, 1996, б. 31]; ул адәмне туқтатмайынча [Кәрими, 1996, б. 32]; анда чықтым, бу низағның, әнә шул қалай чәйнек, әнә шул ат итен [Кәрими, 1996, б. 33]; мондайын сафсаталар [Кәрими, 1996, б. 35]; шул сәғәть [Кәрими, 1996, б. 36]; шул чақлы хозур вә кәйефле [Кәрими, 1996, б. 37]; боларның икесе дә [Кәрими, 1996, б. 38] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: безнең бу әсәремез, ошбу соңғы затлар өчен, ошбу шәһәрдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 264]; бу тарихдан, бу көндә, ул wақытта, бунлар арасында, ошбу бүлемдәдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 266]; бунларның қаберләренә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268]; шу сәбәбдән, бунча йыллар суыны эчтекем, бу шәһәрнең бипалары, бу рәхәтләрне [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 269]; вә шу сәбәбдән ислам дине қабул итмәй қалмышлардыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 281] һ.б.

Сорау алмашлыклары. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: ничөн бу диле җаһилә балаларыңызны вирәсез [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; ничә кәррә ғәҗәйеп сүзләр ишетмеш ирде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 49]; нәрәлисез әфәндем, ниндәй хөкүмәт эше [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 50]; нийә Алла бөйлә җәмиләләр ярата икән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51]; нә ул йарамазлық [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53]; китап кем, сән кем, қанғы китапта димеш ки [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 56] һ.б.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында (1887): Нә вар, нә қарыйсыз, нә улмыш? Кем қәтел итмеш [Бигиев, 1991, б. 221]; исме ничек, үлтерелмеш хатын қайсы нумердә, бу ниндәләйен қатил икән, кем булса кәлдеме, нә wақытда кәлеп, нә wақытда кәтде, нәдән белдең, нә қыййәфәтле, нә төсле [Бигиев, 1991, б. 222]; қайда бу

қәдәр озақ йөрдеңез [Бигиев, 1991, б. 224]; қайсы шәһәрдән йә қайсы аwылдан идеге дә мәғлүм түгел [Бигиев, 1991, б. 224] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында: Ғабделғафурның кем вә ниндәләйен адәм улдығыны бәйән идәмез [Бигиев, 1991, б. 254]; нидән исә дә ғайәт фәқыйрь кемсәнәләр дә күбдер [Бигиев, 1991, б. 255]; қайсы мәдрәсәйә керер, қайсы мәдрәсәдә уқыр, ничек мәслихәт қылурсыз [Бигиев, 1991, б. 258] һ.б.

Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» хикәясендә: ни эшләр идегез [Кәрими, 1996, б. 31]; ничек итеп күрешергә кирәк, ничек итеп йанында, сез кем буласыз, ни эшләргә кирәк, ник соң мин мондайын кийемнәр кийәсең, ниндәйен кийемнәр кисәм йахшы булыр икән [Кәрими, 1996, б. 36] һ.б.

*Қайсы* сорау алмашлыгы исемләшеп кулланыла: қайсы утырған, қайсы қарап бара, қайсы йөри, қайсылары сөйләшә, қайсы мыйық астыннан йылмайып көлә башлады [Кәрими, 1996, б. 37] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: ничә йыллардан бирү араңызда улып [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 270]; қайда варырға белмәй йөрмәктәләр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 272]; изгелек нә йирдә улса [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 275]; үзләренең қайдан килеп, қайда вардыкларыны, асылары нә йирдән идегене [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 282] һ.б.

Кайтым алмашлыклары. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: бу ханә үзе кечек булса да [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 45]; китереңез бәнем үз мәдрәсәмә, үзе дә қара иген эшене эшләйүр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 46]; кәндү милләтене, кәндүсене дошман күрсә дә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 47]; кәнде әхwәлеңә бақасын кәрәк [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 51]; вә үз җенесе улан қадыннар хақында, үзе дә уқымыш қыз иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 52]; кәндесеннән йахшыны тапмайып, кәндүсе дийүр, Ғали бай үзе дә, кәндүсене Ғали байға мөсави кеби тотар [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53]; йаман эшени үзе дә инкяр итмәз [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 54]; кәндүсе чөн бер кемсә сорамақтан бер қапу ачса, хәзрәте рәсүл кәндүсе дә, әйт инде менла үзләренә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 56] һ.б.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында: үзе кәтдекдә, әгәр дә үз-үзене кәтел идмеш улса иде, үз-үземне үлтерәмен дәйү хаты булыр иде [Бигиев, 1991, б. 222]; кәндүсе йығламак мәртәбәсенә ирешмеш, үз-үзе илә сөйләшәйүр [Бигиев, 1991, б. 224]; һәр кәс кәнде

ивләренә кайтып китделәр [Бигиев, 1991, б. 234]; кәндүсе зур буйлы нечкә кеше иде [Бигиев, 1991, б. 236] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында: үзеңездән кечек уланлара ихсан, үзеңездән олуғ вә бөйек уланлара [Бигиев, 1991, б. 256]; кәндүләре күрешмәйә кәлмешләр [Бигиев, 1991, б. 257]; әнә үзең дә хақиқәт хәлне белдең [Бигиев, 1991, б. 268]; үз башың қыйммәтле вә кәрәклерәк, сез үзеңез дә бу эшләрне бездән йахшырақ беләсез [Бигиев, 1991, б. 269] һ.б.

Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» хикәясендә: үзләренең кем булғаннарын [Кәрими, 1996, б. 33]; үзләреннән сорамыйча да аңладым [Кәрими, 1996, б. 34]; үз-үземнән сорадым, үзләре ниқәдәр файда иттеләр, үз урыныма килдем, үземә қалса, бик әдәп вә тәрбийә берлән, үзе ишарәт иткәч [Кәрими, 1996, б. 35]; үзеңне танымыйча [Кәрими, 1996, б. 41] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә үземнең туған аwылыма қайтып [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268]; безләр кәндүләремез холқымызны боздық, бу хосуста үземездән башқаларға үпкә идәргә хақымыз йуқ улса кәрәк, үземездән маһир остаз вә ғалимнәр йитештермәк [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 271]; бәғзелыры үзләренең якын қарендәшләрене, йомышлары олуғ вә үзләренчә нийәтләре һәм дөрест иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 272] һ.б.

Билгеләү алмашлыклары. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: җөмлә исламнар мөсави улдығыны [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53]; җамиғ аwыл аны тәғзим итеп сөйәр икән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 53]; бәхәстә ғаләwәт, мәхәббәт вә һәрбер мөнәсәбәте, һәр нә қәдәр мәхзүн улса да [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 57] һ.б.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында: бунлар барчасы, җәмиғ Қазан халқы [Бигиев, 1991, б. 232]; һәр қайуларының бақышлары [Бигиев, 1991, б. 236]; барчасы бер, һәрбер сүзене сәйед идеп [Бигиев, 1991, б. 237] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында: һәр wақытта [Бигиев, 1991, б. 255, 256]; һәр урында, һәр ғыйлем мәүҗүд улдығы кеби һәр нәүге толлабә [Бигиев, 1991, б. 256]; һәр йаманлық вә кәмлекнең башы [Бигиев, 1991, б. 256]; һәр мәдрәсәләр йахшы [Бигиев, 1991, б. 258]; дөнйада мөмкин булмаған нәрсә йуқ, һәр нәрсә мөмкин [Бигиев, 1991, б. 268]; һәр қайусыны тәфсыйлән нәқел идеп [Бигиев, 1991, б. 269] һ.б.

Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» хикәясендә: бөтен халыҡ көлеште, барысы да ҡулларын бағлап [Кәрими, 1996, б. 32]; мондайын җирләрдә дөнйаның бөтен ҡайғы вә хәсрәтләре онытылып [Кәрими, 1996, б. 37]; һәр кешенең күзе [Кәрими, 1996, б. 37]; боларның һәрбер хәрәкәтләренә [Кәрими, 1996, б. 38] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: мөселманлар җөмләсе сөнни улып [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 266]; һәр эшеңдә шәфҡәт вә миһербанлыҡ илә улмаҡ һәр wаҡытта wазыйфаңдыр, һәр сүзне аңламаҡ, бер Камаләт һәрбер кемсәнәдә табылыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267]; һәр төрле тәкәллеф илә, һәр йирдә бер хозур, һәр урында башҡа бер рәхәт улыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 269]; һәркем үзе эше илә мәшғүл иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 273]; җөмлә хәлләрене үгрәнеп белдем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 283] һ.б.

Билгесезлек алмашлыклары. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: Нунлыларның бәғзеләре, татар менлаларының бәғзеләре [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, 46]; бәғзе кирәк шәйләр алмаҡ өчен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 49]; бәғзеләре ағач таҡтасы илә йабылмыш [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 52] һ.б.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында: бернәчә сәнә мөкаддәм [Бигиев, 1991, б. 221]; бәғзесе ғарәбә илә [Бигиев, 1991, б. 236] һ.б.

Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» хикәясендә: берничә сөальләр [Кәрими, 1996, б. 36]; бәғзеләре керделәр, бәғзелдәре чыҡтылар [Кәрими, 1996, б. 37]; берничә хикәйәләр ишеткәнем бар иде [Кәрими, 1996, б. 38] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: бәғзе берләрнең [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 264]; бәғзеләре урынлашып шөғелләнмәктә вә бәғзеләре нәрсәләре күтәреп иптәшләрене йуғалдып [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 272]; бәғзе бер кемсәнәләрнең [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 277] һ.б.

Юклык алмашлыклары. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: ул һич дошман күзе белән баҡмас иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 47]; һичбер инсан аңа ҡаршы тормаға җәсарәтләнмәз ирде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 52]; һич инанмайурыз, һич инкяр итмәзмен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 54]; эшсез һич йатмас иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 57] һ.б.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында: мылтықтаwышыны һичкем дә ишедмәмеш [Бигиев, 1991, б. 224] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында: һич нәрсәдә сәтр кылмайынча [Бигиев, 1991, б. 265]; һич дә хәбәрдар дәгел иде [Бигиев, 1991, б. 266]; һич әйткәнем йуқ [Бигиев, 1991, б. 268] һ.б.

Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» хикәясендә: һичбер нәрсәгә карамайынча [Кәрими, 1996, б. 31]; һичбер сүз сөйләмичә [Кәрими, 1996, б. 35] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: һичбер айырма улмай [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267]; шәкертләрнең һичбереннән ким дәрәҗәдә дәгел идем, һичкемнең хақы улынмас иде, бер кемсәнәнең wазыйфасы дәгел иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268]; ...һичбер wақыт та хәтеремнән чықармазмын [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 270]; бер кемсәнә юк иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 272] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә мәгърифәтче әдипләр иҗатында алмашлыкларның барлык төрләре дә сайлап алып файдаланылуы аңлашыла.

Сәнгатьле прозаны хикәяләүнең өченче төренә карый торган классиклар иҗатында алмашлыклар.

Зат алмашлыклары. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясендә: синнән күп өйрәнерләр, синең чикле белми торғаннардыр, кеше белүе безгә түгел [Исхакый, 1998, б. 32]; сез генә күп беләсез, мине қулсыз қалдырып, алар булмаса, аларга тел тийерү, ул минем қулымнан китә, безгә дә ақча җибәрер, алар мәктәпкә бирмәсәләр [Исхакый, 1998, б. 32]; син ашарға-эчәргә сорамыйсың [Исхакый, 1998, б. 33] һ.б.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәяседә: мин бу хикәйәнең, миңа әүвәлге халәтеннән, мин онытa алмыйм [Әмирхан, 1984, б. 6]; мин дә килеп утырып [Әмирхан, 1984, б. 9]; алар шатлығына қушылып [Әмирхан, 1984, б. 14] һ.б.

Күрсәтү алмашлыклары. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясендә: ничек җитте шулай көн уздыру түгел [Исхакый, 1998, б. 32]; болар тәхсиле ғыйлемнән башқа [Исхакый, 1998, б. 32]; әнә шул, шуңарға қызығып уқытырға келисең [Исхакый, 1998, б. 33]; шул кешене қуймыйча [Исхакый, 1998, б. 34]; бу йылға җитә [Исхакый, 1998, б. 36] һ.б.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы хикәясендә: бу қаһәр төшкәннәрне, икмәк кимереп йатсыннар шунда

[Ибраһимов, 1974, б. 399]; шул хыйаллар, бу йорт, бу мәдрәсәдер, бу өй [Ибраһимов, 1974, б. 400]; ул тазның, бу кешеләрнең, бу күренешне, анда күргән нәрсәләреннән [Ибраһимов, 1974, б. 401] һ.б.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: бу табғысында [Әмирхан, 1984, б. 6]; бу кеше диңгезе, шул халық диңгезе эчендә [Әмирхан, 1984, б. 8]; бу номеры [Әмирхан, 1984, б. 9] һ.б.

Сорау алмашлыклары. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясендә: ни җаwап бирерсең, ниләр сөйләп торасың, ни эшләр идек [Исхакый, 1998, б. 31]; ққайа илтергә келисең [Исхакый, 1998, б. 33]; ул нинди мәдрәсә соң [Исхакый, 1998, б. 34]; инде қайчан китәсез [Исхакый, 1998, б. 36]; аларға ничек доға қылыйм [Исхакый, 1998, б. 37]; қайсы урамда торалар [Исхакый, 1998, б. 40] һ.б.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә: нигә ул мәдрәсәләрне себермиләр, нигә чүпләрене түкмиләр, нигә бу қәдәрле пычрак тоталар [Ибраһимов, 1974, б. 402]; нишләп бу сәнә мәдрәсәдә шәкерт бик аз күренә [Ибраһимов, 1974, б. 403]; бу нинди шәкерт, син кем, кем угылы, син монда нигә килдең [Ибраһимов, 1974, б. 404] һ.б.

Кайтым алмашлыгы. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясендә: үземнең бәхетсезлегемне уйламас идем, үзең күңелеңә сал, үз кирәгемне белсәм [Исхакый, 1998, б. 31]; дөнйа үземез рәхәт яшәп [Исхакый, 1998, б. 32];. үзем шул йаңы мәктәпкә бирергә келим, үзе дә қарап торған [Исхакый, 1998, б. 34]; үзләренең күпме ақчалары бар икән [Исхакый, 1998, б. 35] һ.б.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы хикәясендә: үзенең барып торачақ, үзенең әүwәлге хыйалында [Ибраһимов, 1974, б. 400]; үзенә бәрабәр [Ибраһимов, 1974, б. 403]; үзең өчен аш пешерү [Ибраһимов, 1974, б. 404]; үзләре бик күбесе қарадылар [Ибраһимов, 1974, б. 405] һ.б.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: бер татар скрипач үз таснифы, үзенең чын дусты-скрипкасы белән, бөтенләй үз-үземнән җуйалып [Әмирхан, 1984, б. 13]; ...үзенең җазибәлеге белән [Әмирхан, 1984, б. 14] һ.б.

Билгеләү алмашлыклары. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясендә: Қазанда бөтен мәдрәсә, бөтен Қазан йортында [Исхакый, 1998, б. 34]; бөтен халық ис-

ләре китеп торырлар, бөтен мәчет халқы доға қылырлар [Исхакый, 1998, б. 39]; бөтен ғомеремне [Исхакый, 1998, б. 48] һ.б.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә: һәр көн қар вә йағмурлар яwып [Ибраһимов, 1974, б. 399]; бөтен дөнйаны болыт вә қараңғылық қаплады, бар ғомерләрене урамда уйнап үткәргән [Ибраһимов, 1974, б. 399]; һәммәсе дә башқа-башқа эшләр, һәммә адәмнәр илә күрешеп, ишек төбендә һәртөрле чүпләр өйелгән, һәртөрле қомғаннар [Ибраһимов, 1974, б. 401] һ.б.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: һәммәсе ғайет белән тәбрик итәләр [Әмирхан, 1984, б. 8]; бөтен клубны тутырған звонок таwышыннан [Әмирхан, 1984, б. 9]; җырлаучылар да һәрберсе үзенә махсус бер ләтафәт белән, һәркемнең күзендә бер шатлық, һәркем урыныннан қузғалды, бөтен халық үлде, бөтен зал мөҗәссәм қайғы хисе белән тулды [Әмирхан, 1984, б. 13] һ.б.

Билгесезлек алмашлыклары. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясендә: әллә қайа мәдрәсәләргә [Исхакый, 1998, б. 32]; шунда бәғзе кешеләр [Исхакый, 1998, б. 34] һ.б.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә: әллә нинди өлкән вә йахшы өй булыр, әллә ниләр йазып чобарлап бетерелгән [Ибраһимов, 1974, б. 400]; әллә ниләр бар, әллә ниләр йазылған йәмсез өстәлләр [Ибраһимов, 1974, б. 401]; берничә суқыр Қоръән уқый [Ибраһимов, 1974, б. 401] һ.б.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: электрик фасылында берничә кәшфийәт [Әмирхан, 1984, б. 7]; кешеләрнең бәғзеләре бөтенләй Йаурупача, бәғзеләре бөтенләй шәрекъча, бәгъзеләре дә һәр икесеннән иң гүзәлләрен алып, бәғзеләре буфетка кереп ашыйлар, бәғзеләре қулымны қысалар, бәғзеләре дә үбәләр [Әмирхан, 1984, б. 8]; әллә нәрсә уйнап утыралар, тирәсендә дә әллә ниқәдәр йәшләр, әллә ничә ғыйнванда гәзитәләр арасыннан [Әмирхан, 1984, б. 9]; рояль йанындағы қыз белән нәрсәдер сөйләште [Әмирхан, 1984, б. 12] һ.б.

Юклык алмашлыклары. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясендә: мин һич белмим, мин бирүләрен бер дә уйламыйм [Исхакый, 1998, б. 47] һ.б.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә: үзенә бәрабәр һичкем вә һич мәдрәсә йуқлығыны аңлатты [Ибраһимов, 1974, б. 403] һ.б.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: һичкем тын алырга җөрьәт итми иде [Әмирхан, 1984, б. 13]; бу көн һичбер җирдә күңел ачарлык бернәрсә дә юк икәнчелеген [Әмирхан, 1984, б. 16] һ.б.

*Кыскача нәтиҗәләр.* Мисаллардан аңлашылганча, күрсәтелгән вакытта язылган әсәрләрдә алмашлыкларның барлык төркемчәләре дә кулланылышта була. Һәр автор, башка барлык чаралар кебек үк, алмашлыкларны да максатына туры килерлек дәрәҗәдә сайлап ала, нәтиҗәдә, алмашлык төркемчәләренең берсе ешрак кабатлана, икенчеләренең сирәгрәк файдаланылуы күзәтелә. Гомумән алганда, әлеге сүз төркеменә караган язма традициянең дәвам ителгән хәлдә, хәзерге әдәби тел нормасының да тотрыклылануга баруы күзәтелә.

## 5.6. Фигыль

Төрле тематик һәм семантик төркемчәләргә бүлеп карарга мөмкин булган сүзләрнең, зат һәм предметның эшен яки хәлен процесс рәвешендә белдерүе ягыннан гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә лексик-грамматик яктан гомумиләшеп, морфологик үзенчәлеге ягыннан, зат-сан, барлык-юклык, юнәлеш, дәрәҗә, наклонение, заман категорияләре хас булган, исем һәм башка сүз төркемнәре белән бәйләнештә, җөмләдә хәбәр һәм башка кисәкләренең вазифасын үти алучы *фигыль* дип атала торган сүз төркеменә караган сүз һәм сүзформалар XIX гасыр – XX йөз башында төрле жанр-стильдә язылган текстларда кулланылышта була. Шуның белән бергә, әлеге сүз төркеменең һәр категориясендә үз дәвере өчен зарури үзенчәлекләрнең дә чагылыш табуы күзәтелә.

Төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасында (морфология) (1988), «Языки мира» дип атала торган энциклопедик хезмәттә дә (1997), фигыльнең һәр категориясе җентекләп өйрәнелә. XIX гасыр ахыры – XX йөз башында, татар теле фәнни тикшерелеп язылган грамматика, сарыф вә нәхү дәреслекләрендә, фигыльне өйрәнүгә киң урын бирелә. Г. Фәезханов «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» (1887) хезмәтендә, исемнәр кебек үк, фигыльләрне дә эзлекле-мантыйклы итеп тикшерә. Зат кушымчаларын ул «замиры шәхсый» дип атый, фигыль заманы белән бергә карый: «...Фигыль заманы дип шундай бер эшкә дәлаләт кыйлган кәлимәне атыйлар ки, ул кәлимәдә зат вә заман мөляхәзә кыйлыныр...» [Фәизхан, 1887, б. 18]. Әлеге хезмәттә һәр заманны барлыкка китерә торган «замиры шәхсыя»лар аерым-аерым

күрсәтелә бара, I зат күплектә *-быз* (بز-) формасы белән бирелә: *язам, язасән, яза, язабыз, язасыз, язалар* [Фәизхан, 1887, б. 22].

К. Насыйри «Әнмүзәҗ» (1895) китабында заман күрсәткечләрен хәреф дип атый [Насыйри, 1895, б. 51; 1975, б. 71], сүз тезмәләренә мөнәсәбәтле рәвештә, ягъни *мән эчәмән, сән йазарсән, ул китабны мән йаздым, сәң күб йокладың* кебек мисалларны аңлатканда, зат кушымчалары «замиры шәхсый фагил» дип атала [Насыйри, 1895, б. 71–72; 1975, б. 92–93].

М. Өметбаев үзенең «Татар нәхүсенең мохтәсары» (1901) дәреслегендә зат кушымчаларын төрлечә атап карый: «...Фигыльләрдә һәм ике сан вар, бере ялгыз (мөфрәд), бере күмәк (җәмгъ) һәм өч нәүгъ вәҗһә бар (төркичә йөз яки бит, фарсыча нөймә диерләр)... әмма һәрбер заманга фигыльнең әмере асыл улыб ахырына бәгъзе хәреф яки кисәк кушылып сарыф идәр». Г. Фәезхановтан аермалы буларак, М. Өметбаев, К. Насыйри кебек үк, I зат күплектә *-мыз* (مز-) формасын күрсәтә [Өметбаев, 1901, б. 22–23].

Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) хезмәтендә фигыльнең заман һәм зат белән төрләнеше аерылып карала: «Фигыль төрлекләре безнең телебездә гомумән ике рәт була: 1) заман төрлекләре, 2) хәбәрлек төрлекләре. ...Хәбәрлек төрлекләре гомумән «минлек, синлек, уллык» дигән өч затка (сөйләүче, тыңлаучы һәм чит затларга) нисбәт ителеп, япсарылып, аларның да ялгыз һәм күп булуларына карап, алты төрдә килә... Хәбәрлек төрлекләре, шулай итеп, «зат алмашлары» белән тиндәшләнә» [Алпаров, 1945, б. 87; 2008, б. 130].

В.Н. Хангилдин грамматикасында фигыль сүз төркеменә хас булган барлык категорияләр дә тикшерелә, һәрберсенең өйрәнелү тарихы яктыртыла. Бу хезмәттә фигыльнең эш (действие) яки хәлне процесста белдерүе аның төп семантикасы, әлеге мәгънә аның грамматик категорияләре белән катлауланып белдерелә, әнә шул мәгънә һәм формалар фигыльнең грамматик билгеләрен, аның грамматик категорияләрен тәшкил итәләр, шулар йөзендә фигыль үзенә башка бер сүз төркеме булып аерыла, дип бирелә [Хангильдин, 1954, б. 160–263]. Академик басма буларак дөнья күргән «Татар теле грамматикасы»нда фигыльгә хас булган төп мәгънәнең грамматик категорияләр белән катлауландырылып белдерелүе, функциональ-семантик кыр яки категория дип, махсус терминлаштырылып тикшерелә, ягъни грамматик формаларны сөйләмгә (контекстка) бәйләп карау юнәлеше көчәя. Фигыльнең

затланышлы формалары, функциональ-семантик яссылыкта тикшерү принцибына нигезләнеп, ике яссылыкта алып барыла: «1) персональлек (затка караганлык һәм зат категориясе), темпоральлек (заманга караганлык һәм заманнар системасы), модальлекне (наклонениеләр системасы) өйрәнүдә анализ башта формадан мәгънәгә таба алып барыла. Синтагматик, ягъни контекска бәйле мәгънәләр ике төргә аерыла: а) форманың нигез мәгънәсен (темпоральлек, модальлек һәм персональлекне) үзгәртми торган мәгънәләр, ә) контекст тәэсирендә төп семаларның (мәгънә өлешләренең) нейтральләшүе һәм күчерелмә мәгънәләрнең барлыкка килүе; 2) мәгънәдән формага таба алып барыла. Анализ өчен нигез итеп функциональ-семантик кыр эчендәге төп грамматик категориянең мәгънәсе алына, һәм бу мәгънәнең башка фигыль формалары белән реальләшүе карала. Димәк, функциональ-семантик категория, грамматик категорияләрнең мәгънә төзелешен һәм формаларын өйрәнүне тел дәрәҗәсендә (парадигматикада) гына түгел, бәлки аларны сөйләм вакытында, тел күренешләрен сөйләм белән мөнәсәбәттә (синтагматикада) өйрәнүне дә күздә тота» [Татар грамматикасы, 2002, б. 116–121].

Теләсә кайсы чорда иҗат ителгән текстны (язма сөйләмне) анализлау эшендә әлеге теорияне нигез итеп алырга кирәклек аңлашыла. Гамәли яктан караганда, Л. Җәләйнең әлеге нәзарият формалашканчы ук язылган «Г. Тукай телендә фигыльләр» дигән күләмле мәкаләсе үрнәк була ала. Л. Җәләй шагыйрь иҗатында исем фигыльләрнең кулланылышын тикшереп, мондый нәтиҗәгә килә: «...Димәк, Г. Тукайда, исем фигыльләр, биш формада: 1) бармак, 2) бару, 3) барырга, 4) бармага, 5) бармакчы – формаларында кулланыла һәм болар үзара бер-беренең функцияләренә дә керешәләр. Бу күренеш Г. Тукайның татар телендәге байлыкны – сөйләү телендәге байлыкны , әдәби телгә кертүдә ничаклы оста һәм иркен эш итүенә дәлил булып тора. ...Шуның аркасында аның теле сыгылмалы, киң катлау хезмәт массасының йөрәгенә ятышлы тел дәрәҗәсенә күтәрелә алган бит...». Шушы ук мәкаләдә, «Тукай телендә боерык фигыльләр үти торган төп функцияләр» дигән баш астында, әлеге фигыльнең тугыз вазифасы санала, дөрес, монда теләк фигыль белән боерык фигыль бергә каралып, түбәндәге мәгънәләр күрсәтелә: 1) боеру, кушу, йөкләтү; 2) киңәш бирү, юату; 3) теләк, омтылу; 4) эндәш-чакыру; 5) иркәләү катнаш үтенү; 6) шелтә, рәнҗүле ялвару; 7) тулысынча бирелү, буйсыну; 8) үз алдыңа уйлану һәм сорау кую; 9) каушап калу. Боерыкларны

эчке диалогта бирү, укучы белән сөйләшүдә куллану дигән үзенчәлек алты төргә бүленә:1) үз фикерен раслату өчен укучыга сорау кылу, мөрәҗәгать итү; 2) укучының дикъкатен арттыру; 3) артык сүз сөйләргә урын калдырмаганлыкны күрсәтү; 4) гүяки тирән бер сер сөйләгәнен алдан әйтеп кую; 5) фикерне «мәҗбүри» сөйләгәнлеген әйтү өчен; 6) ялвару; боерык фигыльгә ярдәм фигыле кушып, нечкә тойгы белән әйтелгән теләк; боерык фигыльләрнең кире шарт функциясендә кулланылуы. Мәкаләдә автор түбәндәге нәтиҗәгә килә: «Г. Тукайда боерык фигыльләр үз функциясен үтәгәндә, ун төрле төсмерне чагылдыралар була. Бу, беренчедән, татар телендәге боерыкларның ничаклы бай төшенчәле икәнлекләрен күрсәтсә, икенчедән, шагыйрьнең шушы байлыктан оста итеп файдалана белүе турында сөйләп тора. ...Г. Тукай телендәге боерыкларның үзләрен генә күзәтеп тә ни кадәр зур байлык барлыгын күрә алабыз. Тукайның бу байлыкны матур итеп, тирәннән сурәтләү, төшенчәләр бирү чарасы итеп куллана алуы да аның чын-чыннан халык шагыйре булганлыгын күрсәтеп тора булса кирәк» [Җәләй, 1938, № 4, б. 58–66]. Л. Җәләйнең «Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар)» хезмәтендә аерым фигыль төркемчәләренең форма һәм мәгънәләре язма истәлекләрдән алынган күпсанлы мисаллар белән аңлатыла, тел күренеше булган форманың әсәр эчтәлегендә ни рәвешле катлаулануы күзәтелә [Җәләй, 2000, б. 142–280]. Әмма бу юнәлеш алга таба киңәйтелми.

Бер үк язма истәлекне берничә халык үзенеке дип күрсәтергә теләгән вакытларда, әсәрнең татар халкына, иске татар теленә дә мөнәсәбәте барлыгын исбат итәргә кирәк була. Бу юнәлештә, башка тел чаралары белән бергә, фигыль сүз төркеменең категорияләренә караган аерым формалары да шушы максатка туры китерелеп анализлана. Мәсәлән, Җ. Алмаз XX гасырның 60 нчы елларында «Кыйссаи Йосыф» поэмасын өйрәнеп язган монографиясенең «Некоторые морфологические особенности языка «Кысса-и-Йусуф» дигән бүлекчәсендә, К. Броккельман тарафыннан «булуман», «салуман», «алурга», «белмәз», «ишләмәзлек» һ.б. сүзформаларның татар укучысына аңлашылмый дип белдерелүенең хата булуын, әлеге формаларның әсәрне күчереп язучыларга да, билгеле бер дәрәҗәдә тарихи үзгәреш алуларына карамастан, хәзерге укучыларга да яхшы таныш булуына игътибарын юнәлтә [Алмаз, 1987, б. 245–255].

Алга таба язма истәлекләрне тикшерүчеләр тарафыннан әлеге юнәлеш үстерелә һәм киңәйтелә барды. Әмма язма истәлекләрне

өйрәнүдә ныклы бер системага салына алмады. Я.С. Әхмәтгалиеваның «Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы» хезмәтендә, барлык категорияләргә дә игътибар ителеп, «Кисекбаш китабы»нда «категория залога, аспект, категория лица, наклонения: изъявительное, повелительное, желательное, условное; неличные формы глагола: причастие, деепричастие, инфинитив; словообразование глагола, сложные глаголы» дип, мисал буларак, грамматикада күрсәтелә торган һәр категориягә хас булган формаларга әсәр эченнән сайлап алынган мисаллар күрсәтелә [Ахметгалеева, 1979, с. 88–101]. Ф.М. Хисамованың, XVI гасыр – XIX йөз башына кадәр Россиядә функциональ кулланылышта булган иске татар телендәге эш кәгазьләре тикшерелеп язылган «Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX вв.)» хезмәтендә дипломатик актлар, грамота, манифест, башка документлар, XVI–XVII гасырларда, XVIII гасырның беренче яртысы, XVIII гасырның икенче яртысы – XIX йөз башы дип аерып тикшерелә, фигыльгә караган тикшерү, «...наиболее активно выступает...» дип, язма текстта актив файдаланыла торган категория анализлана. Болар, гадәттә, үткән заманнар, хәзерге-киләчәк заман дип, заман категорияләренә карый, затланышлы теләк фигыль, затланышсыз фигыльләр [Хисамова, 1999, б. 67–69]; *-а, -ә* формалы хәзерге заман, *-ыр, -әр (-ур, -р)* күрсәткечле хәзерге-киләчәк, *-ды, -де* формалы категорик үткән заман, аналитик *-ган ирде, -ып ирде, -а ирде, -гай ирде,* III зат боерык фигыле, затланышсыз фигыльләр [Хисамова, 1999, б. 84–86]; *-а, -ә* формалы хәзерге заман, *-ды, -де* формалы категорик үткән заман, результатив *-ган* үткән-субъектив, *-уб, -үб (-ып, -еб),* төгәлләнмәгән үткән заман – *-адур ирде,* киләчәк *-ур, -үр,* оптатив – *-гай, -гай ирде,* затланышсыз фигыльләр [Хисамова, 1999, б. 113–115] һ.б. Аңлашылганча, фигыль категорияләре текстта актив кулланылуларына карап рәткә куела.

Башка галимнәрнең хезмәтләрендә дә язма истәлекләрдә фигыль категорияләренең кулланылышы, асылда, хәзерге әдәби телдә урнашкан тәртиптә, ягъни затланышлы/затланышсыз дип бүленеп, хикәя, теләк, боеру, шарт наклонениеләре һәм затланышсыз булган сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль, инфинитив дип бүленеп тикшерелә. Димәк, язма текстны өйрәнү барышында анализны хикәя фигыльнең заманнарына мөнәсәбәтле, аларның мәгънә һәм формаларының парадигмаларын барлап, синтагматик-функциональ мөмкинлекләрен аңлатудан башлау уңай ысул булып санала.

XIX гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән әсәрләрдә фигыль категорияләренең кулланылышын да шушы тәртиптә тикшерергә кирәклек аңлашыла. Әмма фигыль турында гомуми төшенчә бирелә башлаганда ук, ассызыклanганча, хикәя фигыль, заманнар системасы (темпоральлек) белән генә түгел, фигыльнең төп билгеләреннән берсе булып исәпләнә торган зат категориясе (персональлек) һәм эш-хәлнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен махсус кушымчалар белән белдерә торган наклонение (модальлек) белән дә тыгыз берлектә карала. Әлеге мәсьәлә хәзерге татар теле белемендә җентекләп аңлатыла. Бу урында, күрсәтелгән вакытта иҗат ителгән әсәрләрдә заман категориясенең кулланылышын мөмкин кадәр объектив аңлау һәм шул вакыттагы үзенчәлеген дөрес күрсәтү максатыннан, кыскача гына, хикәя фигыльнең зат һәм наклонение категорияләре белән хикмәтле мөнәсәбәте турында әйтеп китү урынлы булыр.

Хикәя фигыльнең заманнарын, фигыльнең нигез формаларыннан берсе буларак, эш яки хәлнең башкаручыга мөнәсәбәтен сөйләүче күзлегеннән чыгып зат категориясе белән бәйләнеше турында белдергәндә, фигыль, сүз төркеме буларак, тулы күләмдә фигыльнең затланышлы формаларында реальләшүен истә тотарга кирәк. Зат категориясенең һәр өч затта берлектә һәм күплектәге тулы, кыска кушымчалы зат-сан белән төрләнеш парадигмалары булуын, 1 нче төр зат кушымчаларының хәзерге, киләчәк, нәтиҗәле үткән заманнарга, 2 нче төр кушымчаларының хикәя фигыльнең калган үткән заманнарына һәм кыек наклонениеләргә кушылуын белергә тиешбез [Татар грамматикасы, 2002, б. 175–177].

Хәзерге татар әдәби теле белән чагыштырган вакытта, XIX гасыр – XX йөз башында язылган текстларда, эш яки хәлнең кем тарафыннан башкарылуын сөйләүчегә мөнәсәбәтле рәвештә белдерә торган зат категориясенең парадигматик һәм синтагматик мәгънәләренең күрсәткечләре сан ягыннан артык булуы күзәтелә, чөнки монда традицион нормаларны куллану (*-мән, -мыз, -з, -сән, -ңыз, -дыр* һ.б.) дәвам ителә һәм җанлы сөйләмә формалар да *(-быз, -гыз)* язма әдәби вариант булып файдаланыла. Әлеге әдәби нормалар кулланылган вакытта, бер үк зат кушымчаларының, төрлечә языла-әйтелә алуына нигезләнгән, графо-орфографик вариантлылыклар хасил була: I зат берлектә *-м* (م-), *-мән* (من-), *-мен* (من-); I зат күплектә *-мыз* (مز-), *-з* (ز-), *-быз* (بز-); *-к* (ق-,ك-); II зат берлектә *-сән* (سن-), *-сың* (سنك-); II зат күплектә *-сыз* (سز-), *-ңыз* (نكذ-), *-гыз* (گز-); III зат берлектә – нуль форма

һәм *-дыр* (-در); III зат күплектә *-лар* (-لار), *-ләр* (-لر) һәм *-лардыр* (-لاردر), *-ләрдер* (-لردر).

Зат категориясенең әдәби норма һәм норма вариантлылыгын тәшкил итә торган парадигмасыннан теге яки бу стиль яисә аның берәр төренең таләбе белән махсус рәвештә аерым бер берәмлегенең сайланып кулланылуы функциональ-стилистик вариантлылыкны барлыкка китерә.

Эш яки хәлнең бер яисә берничә кеше (субъект) тарафыннан башкарылуын белдерә торган сан категориясе затланышлы фигыльләргә генә хас булганга [Татар грамматикасы, 2002, б. 177], зат һәм санны белдерә торган кушымчалар да бер үк була. XIX гасыр – XX йөз башында язылган текстларда зат категориясенә хас булган әдәби нормалар, норма һәм функциональ-стилистик вариантлылыкның барысы да, нигездә, сан категориясенә дә туры килә.

Фигыль категорияләрен язма текстларда, аерым авторның сөйләм берәмлеге буларак, ягъни билгеле бер стиль яисә аның берәр жанры текстында кулланылуы күзлегеннән чыгып өйрәнгән вакытта, эш яки хәлнең чынбарлык белән бәйләнешен, сөйләүче карашыннан чыгып, аның мөнәсәбәте аша билгели торган наклонение категориясен тикшерү аеруча әһәмиятле була. Бу мәсьәләгә киңрәк тукталу сорала. Татар телен фәнни өйрәнеп язылган беренче грамматикаларда наклонение дип атала торган төшенчәнең мәгънәсе, билгеле бер дәрәҗәдә, заманнарны өйрәнү барышында аңлатыла. Г. Фәезханов үзенең хезмәтендә, заманга билгеләмә биргәндә, фигыль заманында, вакыт төшенчәсе белән бергә, затның да «мөляхәзә кыйлынуы», ягъни игътибарга алынуы күренешенә басым ясый [Фәизхан, 1887, б. 18]. Үткән заманның *мазый шөһүди* һәм *мазый нәкъли* дип атала торган ике төре булуы күрсәтелә, ягъни шаһидләргә күрелеп, алар карап торганда булган һәм эш яки хәлнең булуын күреп түгел, ишетеп кенә сөйләүне белдергән үткән заман фигыленең татар теленә хас икәнлеге аңлатыла, аларның барлыкта һәм юклыктагы төрләнеш үрнәкләре бирелә [Фәизхан, 1887, б. 19–21]. Шулай ук, хәзерге заман, хәзерге-киләчәк һәм киләчәк заманнар белән бергә, татар телендә тагын фигыль шарты, үтенү фигыле (йазыйм лә, йаз сана, йазсын ла һ.б.), фигыль әмере дигән фигыльләрнең булуы күрсәтелә.

Г. Нугайбәк «Төрлек» хезмәтендә (1911) татар телендәге фигыльләрне калыплар һәм тармаклар дип бүлгән һәм «...фигыльнең сөйләүчегә карашлыгы аның калыбы була», – дип аңлатканда [Ну-

гайбәк, 1911, б. 43–44] Г. Фәезхановның өйрәтүләрен истә тоткандыр. В.Н. Хангильдин, татар теле белемендә наклонение категориясенең табигатен ачыклаганда әлеге эшчәнлеккә нәтиҗә ясый: «... фигыльдә белдерелгән эш яки хәлнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерә торган грамматик категориянең булу-булмавын ...татар теле белән рус телләрен чагыштыру нигезендә язылган грамматикаларда гына түгел, бәлки татар теленең үз фигыльләрен алып тикшергән кайбер хезмәтләрдә дә очратабыз» [Хангильдин, 1954, б. 230–231]. Татар фигылен наклонение системасында төркемләү, нигездә, XX гасырның 60–70 нче елларында гына гамәлгә керә һәм шактый тәфсилле итеп өйрәнелә. Татар теле белемендә наклонение категориясенең термин-атамасы, аның катлаулы табигате [Хангильдин, 1954, б. 231–232; Тумашева, 1978, б. 5–26, 1986, б. 90), төрки гаиләдәге телләр белән чагыштырылып, форма күрсәткечләренең килеп чыгышы [Сравнительно-историческая..., 1988, б. 324], иске төрки һәм иске татар язма истәлекләрендәге кулланылыш үзенчәлеге (Гыйлаҗев, 1972; Нуриева, 1978; Ахметгалеева, 1979; Бурганова, 1980; Хисамова, 1981; Маннапова, 1982; Хисамиева, 1980, 1989; Нигъматуллов, 1982; Мухаметрахимова, 1990; Алеева, 1990; Шамарова, 1991; Исламова, 1998; Нуриева, 1999, 2004), татар диалектлары һәм сөйләшләрендә наклонение мәгънәләренең ничек файдаланылуы (Бурганова, 1971, 1974; Махмутова, 1978; Рамазанова, 1984, 1996; Хайрутдинова, 1985; Баязитова, 1986; Юсупов, 1986), наклонение төрләрендә мәгънә үсеш-үзгәрешенең контекстка бәйле булуы һәм функциональ-стилистик кулланылышы (Гарданов, 1970; Салехова, 1975; Абдуллина, 1978, 1988; Бәширова, 1979 һ.б.) җентекле итеп тикшерелгән.

Хәзерге татар теле белемендә, эш-хәлнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен махсус кушымчалар белән белдерә торган наклонение категориясе, ике нигездә аңлатыла: а) эшнең чынбарлыкка мөнәсәбәте иң элек эшнең үтәлүе, яки үтәлмәве, реальме, түгелме икәнлеген белдерә торган хикәя фигыльнең заманнарында чагылышы; ә) эшнең реаль булмавын белдерә һәм хикәя фигыльгә каршы куела торган боеру, теләк, шарт һәм кире шарт наклонениеләрендә чагылышы. Бу наклонениеләрнең, сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерә торган модальлек функциональ-семантик категориясенең үзәге булуы ягыннан карала [Татар грамматикасы, 2002, б. 146; Хисамова, 2006, б. 172]. Аңлашылганча, хикәя фигыльнең, фигыльне сүз төркеме итеп тота торган заман категориясе белән бергә, зат һәм

наклонение категорияләре аңлатылганда да төп терәк булуы күренә. Димәк, XIX гасыр – XX йөз башында төрле жанр-стильдә иҗат ителгән текстларда хикәя фигыль (хикәяләү наклонениесе) заманнарының ничек итеп кулланылуын тикшергән вакытта, әлеге мәсьәләләрне истә тотарга тиеш булабыз.

### 5.6.1. Затланышлы фигыль формалары

*Хикәя фигыль формалары.* Билгеле булганча, заман категориясе – материянең яшәеш формасы булган объектив заманның телдәге чагылышы ул. Аны исәпләү ноктасы итеп сөйләү моменты алына. Зат-сан кебек үк, заман категориясе дә фигыльгә хас булган иң әһәмиятле категория санала. Заман мәгънәсе, чынбарлыкта булган яки булачак эш-хәлләрне реаль итеп белдерә торган хикәя фигыльдә тулы чагылыш таба. Хикәя фигыль (индикатив) үткәндә булган (сөйләү моментыннан алда), хәзергә караган (сөйләү моменты белән бер үк вакытта), киләчәктә булачак (сөйләү моментыннан соң) эш һәм хәлләрне заман формалары белән реаль итеп күрсәтә ала. Хикәя фигыль, гадәттә, заман категориясе темпоральлек дип, наклонениенең башка (кыек) төрләреннән аерымланып өйрәнелә [Тумашева, 1986, б. 28–88]. Наклонение хакында гомуми фикер әйтергә кирәк булганда, заман өстәмә рәвештә искәртелә-теркәлә бара.

Хәзерге татар теле белемендә өйрәтелгәнчә, абсолют өч заманның тугыз заман формасында белдерелүе, әдәби норма булып санала [Татар грамматикасы, 2002, б. 121; Хисамова, 2006, б. 176–177]. Татар теленең диалектларында заман категориясенең форма һәм мәгънәләре, әдәби норма белән чагыштырганда, берничә мәртәбәгә күбрәк: хәзерге заман, мәсәлән, әдәби телдә бер форма белән, сөйләшләрдә сигез формада, үткән заман әдәби телдә биш күрсәткеч белән, сөйләшләрдә исә унбиш формада тәгъбир ителә [Юсупов, 1986, с. 10–185; 2004, с. 292–457].

XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган текстларда хикәя фигыльнең хәзерге вакытта әдәби норма булган формаларының да, сөйләшләрдә кулланыла торган кайбер заман күрсәткечләренең дә актив хәрәкәттә булуы күзәтелә. Шуның белән бергә, өйрәнелә торган чорда ерак гасырлардан язма китаби традициянең дәвам ителеше булып килә торган кайбер заман формаларының да гадәти әдәби норма буларак файдаланылулары игътибарны җәлеп итә.

Татар фигылен өйрәнүчеләрнең хезмәтләреннән аңлашылганча, үзләренең сөйләм моментына нисбәтән темпоральлек-вакыт,

аспектуаль һәм модаль мөмкинлекләре, ягъни категориаль-парадигматик мәгънәләре белән берсе икенчесеннән аерыла торган заман төрләре, сүз җае – контекстка бәйле рәвештә, ике нигездәге синтагматик мәгънәгә ия була: а) форманың заман мәгънәсе үзгәрмичә, фәкать мәгънә төсмерләре үзгәргән хәлдә һәм ә) бер заман формасының икенче заманның мәгънәсен белдерү өчен мәгънә күчеше хәлендә. Шуның белән бергә, татар телендә заман белдерә торган мәстәкыйль сүзләргә ярдәмче *бул-* фигыле кушылып, күп сандагы перифрастик фигыль формалары хасил итүе, затланышлы һәм затланышсыз фигыль күрсәткечләренең төрле заман мәгънәләрен белдерә һәм, киресенчә, хикәя фигыль үзе башка фигыльләрнең мәгънәсендә кулланыла алуы, ниһаять, бик күп төрдәге модаль формаларның хәрәкәттә булып, заман мәгънәрен дә алып килә алулары заман категориясен нык катлауландыра [Татар грамматикасы, 2002, б. 139–143].

XIX гасыр – XX йөз башы татар язма текстларында заман төрләренең әдәби норма, норма һәм функциональ-стилистик вариантлылыкларын билгеләгәндә менә шушы өйрәтүләр теоретик нигез итеп алынды.

Өйрәнелә торган чорда үткән заман хикәя фигыльләрнең төрле жанр-стильләрдә кулланылышын җентекләп тикшерү нәтиҗәсендә, аның түбәндәге формаларда чагылыш табуы мәгълүм булды: синтетик төрләре: *-ды, -ган, -мыш, -ып;* аналитик төрләре: *-ды иде, -ган иде, -ып иде, -мыш иде, -а (дыр) иде, -р иде, -йур иде, -а торган иде, -ачак иде, -макда иде, -мак (-лык) иде, -уда иде, -учан иде.*

Хәзерге татар теленең үсеш-үзгәрешенә нисбәтән караган вакытта: *-ды, -ган, -ган иде, -а иде, -р иде, - а торган иде, -ачак иде* формаларының хәзерге татар әдәби теле норма күрсәткечләре булуы [Татар грамматикасы, 2002, б. 121]; *-ды иде, -ып, -ып иде, -учан иде* формаларының диалекталь үзенчәлек булуы [Юсупов, 2004, с. 416–457]; *-мыш, -мыш иде* күрсәткечләренең хәзерге татар телендә стилистик максатлардан файдаланылуы [Абдуллина, 1988, б. 5], *-йур иде, -макда иде, -уда иде, -мак (-лык) иде* формалары язма традициянең чагылышы булуы мәгълүм [Юлдашев, 1965, б. 140, 151].

Аңлашылганча, үткән заман хикәя фигыль өйрәнелә торган чорда, угыз һәм кыпчак телләренә хас булган ике әдәби тел нормасында кулланыла, XIX гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән төрле стиль һәм жанр-төрдәге язма текстларда әлеге заман күрсәткечләре төрле

дәрәҗәдә (актив-пассив) һәм төрле ешлыкта файдаланыла, әмма аларның барысы да үз чорының әдәби нормасы булып санала.

XIX гасырның беренче яртысында иҗат итүче Әбелмәних Каргалый (1782–1833), Һибәтулла Салихов (1794–1867), Шәмсетдин Зәкинең (1825–1865) шигъри-тезмә әсәрләрендә, Йосыф Баласагунлының мөселман идеологиясен куәтләү максаты белән, гарәп-фарсы алынмаларын мул кулланып аристократ абруйлы төрки телдә язылган «Котадгу белек»тән (1069) килә торган традиция дәвам итегә, ягъни гарәп вә фарсы алынмалары мул кулланыла.

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендәге (1845, 1889, 2002) ун хикәядә автор үз чорындагы иҗтимагый тормыш каршылыкларын, тарихта яшәп киткән шәехләрнең эш-гамәлләре, шулай ук «Тәфсире Кәбир», имам Газалиның (1058/9–1111) «Мишкәтел әнвар», Җ. Руми, Аллаһияр әсәрләренә мөнәсәбәт белдереп, укучы күз алдында бара торган рәвештә тасвир итә һәм үз исеменнән нәтиҗә ясап куя. Бу үзенчәлек фигыльләр куллануга тәэсир итә, әсәрдә бара торган вакыйгалар, «диде» дип башлана, персонажларның сөйләме кебек бирелә торган кысада, сөйләшү укучы күз алдында бару формасында дәвам итегә: Диде: Нокраме әлеңдә йәки дөрр, Буйлә мәхкәм дотмақың аслы нәдер? Ул ирәнләр тағы ул дәмдә җаwаб Вирде ул шәйхә, җаwабы ба саwаб... [Каргалый, 1889, б. 2]; *-ды* кушымчалы категорик үткән заман, «диде» дип хикәяләүне башлаганда, әлеге фигыльне «дийә» (әйтә) дип хәзерге заман формасында да кулланып була кебек, ләкин бу очракта, персонажларын күз алдында тоткан авторның үз карашы юкка чыга. «Диде» фигыле бу очракта хикәяләүне алып бару вазифасын үти торган, вакыйгаларның кабатлануын белдерүдә уңайлы форма буларак кулланыла: ...Сәғләбия нәтде дөньйа кәсрәте? Нәйләде Қарунны дөнйа дәүләте? [Каргалый, 1889, б. 2] һ.б. Шул ук вакытта, бу фигыль үзенең синтагматик-күчерелмә, ягъни хәзерге заман мәгънәсендә дә файдаланыла булса кирәк: ...Сәндин ошбу сүзне әйләрмән ғаҗәб Нәтә фәһем әйләмәдең («әйләмисең» мәгънәсендә) ғали нәсаб [Каргалый, 1889, б. 2] һ.б.

Ә. Каргалыйның I заттан бирелә торган лирик кыйтгаларында категорик үткән заман үзенең парадигматик мәгънәсендә, ягъни сөйләү моментыннан алда, сөйләүченең күз алдында булган, тәмамланган, кабатланмаган эш-хәлләрне процесс рәвешендә белдерә: Үтде дәүран, Кичде сәйран: бәне күр..., Йаза-йаза йәш илә тулды күзем, ...бетде сү-

зем. ...Хәсрәт илә аһ итеп, бу назмы қылдым ибтида... Хәзрәтеңә чуқ догалар юлладым, ғали кәрәм... [Каргалый, 2002, б. 116, 117] һ.б.

Шул ук вакытта бу төр фигыльләр дәвамлы, кабатланган эшләрне белдерә торган синтагматик мәгънәсе белән дә кулланыла: Тәндә җаным ничә көн миһман икәндер? Белмәдем, Үтде гомрем, Барысыхөсран икәндер, белмәдем. Дөньйада төздем ғыймарәт, барсы – наданлык белән, Бу ғыймарәт җөмләсе вәйран икәндер,белмәдем... [Каргалый, 2002, б. 122] һ.б.

Категорик үткән заман хикәя фигыльнең I һәм II зат берлек сан барлык һәм юклык формалары: ایلامادونك – әйләмәдүң [Каргалый, 1889, б. 2], بولدى – булды, قيلديلار – қыйлдылар, قالدى – қалды, ايلدى – әйләде, دوتماديلار – дутмадылар, كتديلار – китделәр [Каргалый, 1889, б. 3, 5, 9]; I зат күплек: инсафа кәлүрдек (كلوردك) без дәхи, [Каргалый, 1889, б. 4]; юклык формасының булу-булмавы язылышка тәэсир итми, сорау кисәкчәсе белән килгән вакытта III зат берлек һәм күплектә йай (ى) хәрефе куела: كلديمى – килдеме, II затта йай (ى) язылмый: قايتدنكمو – қайтдыңмы.

Һ. Салиховның «Китабе мәҗмәгыль адәб» хезмәтендә (1856) *-ды* формалы үткән заман хикәя фигыльнең I һәм III зат берлек саны үзенең төп парадигматик, ягъни сөйләү моментыннан алда, тәмамланган, кабатланмаган мәгънәсендә файдаланыла: ...нәзар қыйлдым (قيلدوم) у хәбелнең (арканның) башиға, ...ғаҗәб мәхкәм аны тотдым (توتديم) сәриған (тизлек белән), ...алыб атдым (آتدم) ушал дәмдә шәфирә, ...тоташды (توتاشدى) эчемә ут, йақды җаным [Салихов, 1856, б. 4], ...капуңа йалwари кәлдем (كلديم) қабул ит [Салихов, 1856, б. 5], ...қосурәтем (җитешсезлегемне) ғайан (ачык) итдем (ايتدوم) [Салихов, 1856, б. 8] һ.б. Шул ук вакытта дәвамлы, кабатлана торган эш-хәлләрне белдерү вазифасы белән кулланыла: ...Йөземне қыйблайа тотдым (توتدم) / Қыйраәт телдә йөртдем (يورتديم) [Салихов, 1856, б. 7] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, *-ды* кушымчасы зат формасына кушылганда, *-ум* (وم-), *-им* (يم-), *-д* (د-) формасында була. Һ. Салихов «Әбелмәнихның «Тәндә җаным...» шигыренә» дигән әсәрен Ә. Каргалый стилендә дәвам итә: Дөньйа сәүмәк – ширбәте шайтан икәндер, белмәдем / ...Нәфсем – Иблис илә бер гаһдан икәндер, белмәдем... / Бәсләдем җисмемне даим җәреб ширин нәрем илә/...Қыйлмадым һәр гиз тәффәриқ ғөмремнең миннәтене. ...Авторның «Тәэссеф» («Үкенү») касыйдәсе дә дөньяда эшләгән эшләренә үкенү белән языла, *-ды* кушымчалы үткән заман үзенең кабатлаулы, дәвамлы мәгънәсе белән кулланыла, әлеге мәгънә

лексик чаралар белән көчәйтелә: Илле биш йыл ғөмер сөрдем, рәнҗ-ү-михнәт күрмәдем, / Йидем-эчдем төрле ниғмәт, мәқты ниғмәт чикмәдем / Аһ, бу дәклү дәүләтә һич шөкер ниғмәт итмәдем, / Ғафләт илә үтде гөмрем, әй дәригә, нидәйем? [Татар поэзиясе..., 1992, б. 273].

Г. Кандалыйның иҗатында категорик үткән заман үзенең төрле мәгънәләре белән файдаланыла. Төп парадигматик мәгънәсе белән: ...Бу бала хәсрәте түкте / қара сачләрем башымдин...[Кандалый, 1988, б. 92] , ...Ки бән алдым қаләмемне, йазаем дип сәламемне [Кандалый, 1988, б. 107], Буең күрдем, дидем: әлхәмделилла! / Йөзең күрдем – уқыдым «қөль-һу-алла» / ...Бу хатымны йибәрдем бән пичәтләп [Кандалый, 1988, б. 130].

Кабатланган эшләрне белдерә торган синтагматик мәгънәсе белән: Пароходлар төшкән чакта / Ғазиз балам сәне көтдем... [Кандалый, 1988, б. 93], ...Бүген без утырдық хушлап / Ишан сагышын сагышлап... [Кандалый, 1988, б. 100], ...Тәмам яндырды, көйдерде / Сәнең бу чын сәлам хатың... [Кандалый, 1988, б. 117].

«Сахибҗәмал» поэмасындагы кыйтгалар категорик үткән заман хикәя фигыленең парадигматик мәгънәсе белән, ягъни сөйләү моментыннан алда, сөйләүченең күз алдында булган, тәмамланган, кабатланмаган эш-хәлләрне процесс рәвешендә белдерә торган төп мәгънәсе белән башлана: Бу ғыйшықлық чабы китде / Уфа, Казан да, Сенбергә..., әмма икенче юлда әлеге мәгънәнең дәвамлы булуына ишарә ителә: Бу ғыйшықлық йаманатын / Күтәрдең сән дәхи бергә; Бу ғыйшықлық чабы китде / Саратау берлә Нижнайға / Бу ғыйшықлық бәетләре / Безгә қалды ла вечнайға; Бу ғыйшықлық чабы китде / Сарапул берлә Самарға / Йосыф берлә Зөләйха тик / Атымыз қалды санарга [Кандалый, 1988, б. 418] һ.б. Әлеге үзенчәлекне, ягъни категорик үткән заман фигыленең тәмамланмаган һәм тәмамланган мәгънәләрен бергә куллану ысулын авторның күпчелек шигырьләрендә дә файдалануы күзәтелә: Әйә йил, сән қайа исдең? / Нәчә сахра үтә кичдең? / Туғанымны қайда күрдең / Дәйүб сорам ки анлардин... [Кандалый, 1988, б. 88]. Дәвамлылык аерым сүзләр белән ныгытыла: Йырак йиргә китеп барғач / Ғөмергә хәсрәтең қалды... [Кандалый, 1988, б. 90]. Аерым йулларда шигъри тасвир, рәттән дийәрлек, *-ды* кушымчалы бер үк сүзләрнең кабатлануы белән бирелә: Сәне сайрамаға былбыл йаратды / Бәне йығламаға моңлы йаратды, / Сәне – анда, бәне бонда йаратды / Бәне – сәңа, сәне бәңа қаратды /Сәнең өчен күңелдә ғәм йаратды / Ике күземне тулы қан йаратты... [Кандалый, 1988, б. 435] һ.б.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теленең тезмә-шигъри әсәрләрендә дә, үткән заман хикәя фигыльнең *-ды* күрсәткечле формасы III затка да хас төрләндергечләре белән кулланылып, нигездә, барлык мәгънәләре белән дә чагылыш таба.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1879) әсәренең тезмә өлешендә *-ды* кушымчалы I зат үткән заманның тәмамланмаган, дәвамлы, кабатлаулы эш-хәлләрне белдерә торган синтагматик-контекстуаль мәгънәсе файдаланыла: Бағ-бөстанлар ясатып, қызыл гөлләр салдырдым, / Йефәк түшәү түшәтеп, сунқарымны алдырдым [Татар әдәбияты, 1957, б. 327]. *-ды* формалы үткән заман хикәя фигыльнең II заты да, нигездә, синтагматик мәгънәсе белән сурәт ясау чарасына әверелә: Қарай-қарай қалдың син, күп қыенлар салдың син / Сөйгәнеңдән аерылып, йығлай-йығлай қалдың син / Бутасындан аерылган төйәдәй-буздай қалдың син / Күп тубындан аерылган қошдай-моңдай қалдың син / Ботағындан аерылған гөлдәй сулыб қалдың син... [Татар әдәбияты, 1957, б. 305]. Китерелгән мисаллардан башка бу фигыль тезмә өлешләрдә чагылыш тапмый. Ә. Уразаев-Кормашиның кыйссаларында *-ды* формалы үткән заман хикәя фигыльнең III заты, әсәрнең тезмә өлешләренә караганда, хикәяләүне алып бара торган чәчмә өлешендә еш кабатлана. «Кыйссаи Бүз йегет»тә: Төшендә бер ақ сақаллы кеше әйтде [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 12], ...қызлар сарайының қаршына килеб, сарайны қамап алдылар [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 15], ...көндез сахрада йатды, кичә булса, мағшуқы берлән табышыб йөрер ирделәр [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 16] һ.б. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә: ...бөтен солтанатымны бирсәм кирәкдер, диде. Мең алтын чыгарып дәрвишкә бирде. ...Ходай Тәғалә морадыңны бирсен, диде, ...бақчаға керделәр, ...бер ағачның йанына килделәр, ...күрделәр кем, ...падишаһ әйтде... [Татар әдәбияты, б. 287-288] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, билгеле үткән заман хикәя фигыльнең III заты белән вакыйгалар барышы, аларның эзлекле үсеше белдерелә, эш-хәлләр укучының күз алдында бара кебек тәэсир тудырыла, димәк, бу очракта әлеге фигыль парадигматик мәгънәсе белән кулланыла дип әйтеп булмый.

Ш. Зәки шигырьләрендә *-ды* кушымчалы фигыль төрле мәгънәләре белән кулланыла. «Әй дәрига...»дип башлана торган шигырендә, «калмады» дигән фигыль уналты мәртәбә кабатланып, сөйләүченең күз алдында булган, тәмамланган, кабатланмаган эш-хәлләрне процесс рәвешендә белдерә торган төп парадигматик мәгънәсе белән

кулланыла:...Та Сәне беләм ки, Сәндин ғайре йарым қалмады / Ақызыб күз йашеме дәргяһә сөрсәм башымы / Дәм бә дәм сәңа йалынсам, үзгә кярем қалмады [Гайнетдинов, 2002, б. 40; Юсупов, 2006, с. 188]. «Бән Ходаның...» дип башлана торган шигырендә авторның хис-кичерешләре шундый ук мәгънәдәге фигыльләр белән генә белдерелә: ...Күңлемең күзене йабды гәрде ғавләт қарасы. ...Хәсрәт уды дөшде йақды бәғреми әйнелмәҗәл. ...Туғмады һәргиз анадан бән кеби бичара кол. Шул ук шигырьдә *-ды* кушымчалы фигыльнең барлыгы – тәмамланган, юклыгы исә дәвамлы эшләрне белдерә: Дөрле-дөрле хәсрәт илә тулды калбем бихисаб / Һәргиз икселмәз, мөдам артыр бу күңлем йарасы... [Гайнетдинов, 2002, б. 32–33; Юсупов, 2006, с. 192]. Бу авторның шигырьләрендә *-ды* күрсәткечле фигыль I һәм II зат төрләндергечләре белән кулланыла: باتديم – батдым, بيلدم – белдем, دوشدم – дөшдем, ايتدم – итдем [Юсупов, 2006, с. 186, 190]. Мисаллардан күренгәнчә, дүрт сүзнең өчесендә *-ды* күрсәткече сузыксыз язылa.

Г. Чокрыйның «Шәмгыз зыя» (1883) китабында әлеге кушымча сузык аваз белән языла: ирадә кыйлдым (قيلديم), тәсмия кыйлырга булдым (بولدوم) һ.б.

М. Акмулланың «Даменла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе»ндә (1892) I зат формасы сөйләү моментыннан алда, тәмамланган эш-хәлләрне белдерә торган парадигматик мәгънәсе белән кулланыла: ...Үгәй ана кулында йәтим қалдым (قالدوم), / Андан да бик эрәтем китеп қалдым (قالدوم)… [Акмулла, 1892, б. 4], ...Қазакча шиғырь йаздум (يازدوم) ачық қыйлыб [Акмулла, 1892, б. 9], ...без дә күрдек (كوردوك) уғының атқан йирен [Акмулла, 1892, б. 10] һ.б.

Шул ук форма эш-хәлне күпмедер вакыт дәвам иткәнлеген белдереп тә файдаланыла: Қайда мулла бар дисә, йитеп бардым (باردوم) / Фәқыйрьлектән артық фән күрә алмадық (آلمادوق), / Шәһәр чыгып, алыс йаққа йөрә алмадык (آلمادق) / Мәргәннәрне танырлық халебез бар, / Шул сәбәбдән сабыр қылып тора алмадық (آلمادق)... [Акмулла, 1892, б. 4], ...Без сатдық (صاتدق) меллалықның қоры атын,... [Акмулла, 1892, б. 12]. Күренгәнчә, I зат берлек һәм күплектә мисалларның күбесе сузыклы булып языла. Шул ук вакытта, эш-хәлнең кабатлануы *карай-карай, талай-талай* һ.б. лексик чаралар белән дә бирелә. III зат парадигматик мәгънәсе белән кулланылганда, эшнең билгеле бер вакытка яки урынга караганлыгы чикләнеп күрсәтелә: Қазанда бер фазыйл чықды алмас булыб,... / Мәйданда ул чықарды артық ғайрәт,.. / Хәмде лиллаһ бу диарда бездән чықды / Мәрҗани Шиһабетдин

ахунд хазрәт... / Чықарды татлы суны тирән йирдән [Акмулла, 1892, б. 3]. Бу авторда *-ды* кушымчалы фигыльнең III зат юклык формасы хәзерге заман мәгънәсендә кулланылуы күренә: Адәм камил булмады қайнап пешмәй / Мәхәббәт фәнҗанындан шәрәб эчмәй [Акмулла, 1892, б. 12; 2001, б. 27], Күрәмез тирәзәдин мирзаларды / Үтәде қасымыздан сабай-сабай... Ат менән ни күрмәйде адәм басы... [Акмулла, 2001, б. 68].

Г. Тукай һәм Дәрдемәнд иҗатында билгеле үткән заман хикәя фигыльнең, барлык мәгънәләренең дә, төрле күренешләрне тасвирлау өчен файдаланылуы күзәтелә. Авторларның сәнгатьчә фикер йөртүләре белән бәйле булган әлеге үзенчәлек аерым тикшерүне сорый. Бу урында, берничә мисал гына китереп үтәргә туры килә. Шагыйрьләрнең назик хис-кичерешләре чагыла торган шигырьләрендә, башка тел берәмлекләре белән бергә, I зат үткән заман хикәя фигыльләре дә эзлекле кабатлана. Г. Тукайның «Туган илемә» дигән шигыре: Айрылып китсәм дә синнән, ғомремнең таңында мин, / И Қазан арты! Синңа қайтдым, сөеп тағын да мин, – дип башлана да, – Бу сәбәбдән аңладым мин, и туған җирем синең / Җанға йағымлы икәндер йалкының да дулкының, – дип дәвам ителә. Тасвирлау: Ул таныш қырлар, болыннар тартты әүwәл хиссеми / Тарта торғач, қуймады, қайтарды ахыр җисмими, – дип, III заттагы үткән заман фигыльләре белән көчәйтелә бара [Тукай, 1955, б. 80]. «Пар ат» шигыре: Җиктереп пар ат, Қазанға туп-туры киттем қарап, – дип башлана да, – Шундый уйлар берлә таштай катты-китте башларым / Чишмә төсле, ихтыйарсыз ақты-китте яшьләрем – дип дәвам ителә... [Тукай, 1955, б. 81]. Билгеле үткән заман фигыльләре белән хис-кичерешләрнең тиз алышынуы сурәтләнә. «Иһтида» шигырендә: Табындым, сәҗдә қылдым мин сөйгән җанашның алдында / Өмит иттем wә қурықтым да қызардым һәм оялдым да [Тукай, 1955, т. 2, б. 150] һ.б.

Дәрдемәнднең данлыклы «Бүзләрем мана алмадым» шигыренең барлык аһәңе нәкъ менә категорик үткән заман хикәя фигыльнең парадигматик һәм синтагматик мәгънәләренең бер-бер артлы чиратлашуы белән тасвир ителә: Гәрчә мин дә бар саналдым, Ил қатар сан алмадым; / Илдә йөрдем, хазлар алдым, / Уйласам – сан алмадым / Йанды Мәҗнүн, йанды Фәрһад, / Бер йанып ат алдылар. / Мин, ғариб, мең қат йанып та, / Йандыға саналмадым / Уйлағыз: мәғшуқа меңләр, / Мин ғашыйқ саналмадым... / Дәрдкә дәрман алмадым / Бүзләрем мана алмадым [Дәрдемәнд, 1980, б. 48–50].

Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең II заты, гадәттә, шагыйрьләрнең аерым зат яисә предметка эндәшеп язылган шигырьләрендә файдаланыла. Г. Тукайның «Сөальләр» шигырендә: Йә Ходайа! Нигә төрле-төрле қылдың бәндәни? [Тукай, 1955, б. 125], «Өзелгән өмид» шигырендә: Күз йәшең дә кипмичә йыглап wафат булған әни, / Гаиләсенә җиһанның ник китердең йат кеше?... И моқатдәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз? / Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз ахрысы! [Тукай, 1955, т. 2, б. 95] һ.б.

Г. Кандалый иҗатында: Әйә йил, сән қайа исдең? / Нәчә сахра үтә кичдең?, – дип, табигатьтәге төрле күренешләргә, үсемлекләргә эндәшеп тасвир итү алымы кулланылса, Дәрдемәнд шигырләрендә: ...Килер-килмәс борын гөрләп матур йаз, / Ничөн бөктең, умырзайа, биленңне? / Исәр-исмәс икән таңда җиләс җил, / Ничөн кызғанмадың, түктең гөленңне?... [Кандалый, 1988, б. 21], дип, тирән хис-кичерешләрне тасвирлау чарасы буларак файдаланыла. Дәрдемәнднең күп кенә шигырьләрендә, вакыйгаларның тиз алмашынып, эзлекле үсеше белән тасвирлана торган күренешләрне бирүдә билгеле үткән заман хикәя фигыльнең III заты кулланыла: Ничә бағлар күңелләрдә төзелде / Сары йуллар булып ғамьләр сызылды / Өмидләр, кем, менеп башка тезелде / Ағарған қыл кебек бер-бер өзелде [Дәрдемәнд, 1980, б. 70], ...Ағарды чәч, / Қуарды баш, / Сары юллар сызылды, Өмидләр, кем / ...Өмидләр кем... / Дариғ, бер-бер өзелде!... [Дәрдемәнд, 1980, б. 71] һ.б.

Бу шагыйрьләр иҗатында *-ды* кушымчалы үткән заман хикәя фигыльнең күчерелмә мәгънәдә, ягъни вакытка бәйле булмаган, дәвамлы эш-хәлне белдерә торган хәзерге заман мәгънәсендә кулланылуы күренә: Қаршыларға иң сәда чақ, иң матур чақ җәйге таң, / Шул вақытда уйла, шағыйрь: килде илһам, уйласаң... («Җәйге таң хатирәсе»). Хәл фигыль урынында: Чишмә төсле ихтыярсыз ақты китде йәшләрем... («Пар ат»). Чапты китде Миңлебай чатыр-чатыр / Үтмәгәндер күз ачып-йомған заман, Килде дә йитде Қарәхмәт – қаһреман... («Печән базары...») һ.б. Сыйфат фигыль урынында: Мин, ғариб, мең қат йаныб да, / Йандыға саналмадым... («Бүзләрем...») һ.б.

Шулай итеп, XIX гасырның беренче һәм икенче яртысында иҗат итүче авторларның тезмә әсәрләрендә, категорик-билгеле үткән заман хикәя фигыль үзенең барлык мөмкинлекләре белән кулланылган дип әйтә алабыз.

Үзеннән-үзе аңлашылганча, категорик үткән заман хикәя фигыль XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган төрле жанр-стильдәге

текстларда да кулланыла, әмма әсәрнең кем тарафыннан һәм ничек итеп хикәяләнүенә бәйле рәвештә, аның төп-парадигматик һәм контекстуаль-синтагматик мәгънәләре, ягъни аспектуаль һәм модаль мөмкинлекләре төрле текстта төрлечә реальләшә. Бу хәл К. Насыйри иҗатында ачык күренә, чөнки бу галим үз чоры әдәби теленең барлык стильләрендә хезмәтләр язган, әлеге текстларда категорик үткән заман хикәя фигыльнең төрле мәгънәләрдә чагылыш табуы һәм төрле ешлыкта кабатлануы күзәтелә.

Мәгълүм булганча, «Кырык вәзир кыйссасы»ның (1868) барлык хикәятләре дә бер калыпта, «хатын әйтде» яисә «вәзир әйтде» дип башлана, хикәяләү барышында әлеге штамп дәвам итеlә: ...уғлан хуҗасына әйтде, атасы әйтде, қазый әйтде, қыз әйтде, кияү әйтде, хуҗа әйтде, хорасани әйтде, қарт әйтде һ.б. (Насыйри, 1975). Шундый ук хикәяләү алымы «Кырык бакча» һәм «Фәвакиһелҗөләса» (1884) текстларында да саклана: ...Лоқман хаким әйтде, Аристо әйтде, Ибраһим Әдһәмгә бер кеше әйтде, Йахья бине Әқсам әйтде, Нәүширвәнгә әйтделәр, Сәһел бине Һарун әйтде, галим әйтде, йорт ийәсе әйтде, саилнең уғылы әйтде, бер саилгә әйтделәр һ.б. Бу контекстта *-ды* күрсәткечле категорик үткән заман хикәя фигыльнең автор тарафыннан акыллы кешеләр сөйләгән сүзләрне бәян итеп баруын барлыкка китерә торган төп чара булуы аңлашыла, әмма монда әлеге фигыльнең вакытны (сөйләү моментына кадәр булуы), аспектуаль (бер мәртәбә эшләнәме, кабатланамы), модальлекне (күрелеп үтәме, күрелмичәме) белдерү мөмкинлеге тулысынча реальләшә дип әйтеп булмый, чөнки *-ды* форманты урынына хәзерге заманны яисә үткән заманның башка формаларын куйганда да, хикәяләүгә зыян килми. Мәсәлән, хатын әйткән, вәзир әйткән, хатын әйтә иде, әйтер иде, әйтә торган иде һ.б.; категорик үткән заман хикәя фигыле монда үзенең күчерелмә мәгънәсендә кулланылган дип тә әйтеп булмый, ул кеше сүзен сөйләү өчен җайлашкан, барлык заман формаларының бер инварианты кебек файдаланылган булса кирәк.

Әмма башка формалар кулланылмыйча, бәлки нәкъ менә *-ды* формасының файдаланылуы хикәяләүнең барышын үзенчә җанландыра, чөнки, билгеле бер дәрәҗәдә, күрелеп үтү төсмере сизелә, димәк, К. Насыйриның бу алым белән хикәяләнә торган әсәрләрендә, категорик үткән заман хикәя фигыльнең вакыт һәм аспектуаль мөмкинлегеннән аермалы буларак, әлеге заманның модальлек төшенчәсе бөтенләй хәрәкәткә китерелмәгән дип әйтә алмыйбыз.

Ә инде *-ды* күрсәткеченең хәзерге заман формасы белән алмаштырылуы, хикәяләнә торган хәлләрне автор белән бергә укучы да күрә ала кебек тоела, тәэсирне көчәйтә, «Әбүгалисина кыйссасы» (1881) хәзерге-киләчәк заман фигыле белән башлана: Ривайәне әхбар wә нәқыйләне асар ошбу тариқ үзрә ривайәть қыйлыр ки, ...ривайәне ширин кәләм, яғни тәмле-тәмле хикәйәтләрне ривайәть қыйлгучылар шөйлә ривайәть қыйлырлар ки... [Насыйри, 1889, б. 3; 1974, б. 3]. Бу төрдәге башлам хикәяләү барышында авторга үзенең мөнәсәбәтен ачыграк күрсәтергә киң мәйдан ача, әлеге әсәрдә, алдагылары белән чагыштырганда, кеше сүзен сөйләү штампы йомшара, вакыйгаларның барышы тагын да ныграк җанлана төшә, ләкин «Әбүгалисина кыйссасы»нда да *-ды* кушымчалы фигыльнең вакыйга-хәлләрне алып баруда төп көч булып саклануы дәвам итәлә.

К. Насыйриның әлеге әсәрендә, баш җөмләсе билгеле үткән заман хикәя фигыль белән күрсәтелә торган, бер типтагы иярчен тәмамлык җөмләләр кулланыла, иярчен җөмләләрнең хәбәрләре әле хәзерге заман, әле үткән заман кушымчасы белән бирелә: Кибетенә килеп күрде: Әбүгалисина тәмам хәлwәче булып, хәлwә сатып ята. Ул арада патша қызы күзен ачып күрде: үзенең сараенда, хөҗрәсендә утырыр. Әбүгалисина күрде: ахры асалар. Күрде: сәясәт килә. Күрделәр: хәлwәфруш сәйәсәт мәйданындан ғаиб булып китде, ...чылбырлар чылтырап қоелыб қалды: шәһәрнең қапқасындан бер гөруһ ғаскәр чықды һ.б. Әлеге мисаллардан аңлашылганча, хәзерге заманның формалары *(-а, -р)* белән күрелеп үткән заманның аффиксы *-ды,* берсен икенчесе алмаштырып килә ала торган, вариантлар хасил итә.

К. Насыйриның бу әсәрләрендә, әлбәттә инде, *-ды* формантлы категорик үткән заман хикәя фигыльнең парадигматик һәм синтагматик мәгънәләре дә чагыла торган мисал-җөмләләр булуы инкяр ителми, әмма вакыйганы алып баруда, әсәрдә әйтелергә тиешле төп фикерне укучыга җиткерүдә төп көч булып, билгеле бер дәрәҗәдә модальлеге хәрәкәткә китерелгән *-ды* кушымчалы фигыльнең, берничә заманга нигез була алу, ягъни «инвариант заман» дип атарга мөмкинлеген файдалану дәвам итәлә.

К. Насыйриның фәнни хезмәтләрендә, аның үз исеменнән бирелә торган сүз башларында, категорик үткән заман хикәя фигыль төрле мәгънәләрендә файдаланыла: «Әхляк рисаләсе»ндә, әлеге фигыль синтагматик мәгънәсендә, үткәндә булган эшнең дәвамлы булуын белдерә: Наданлық һәр қачан сине үкендерер, һай гомерем

үтде, сабақ уқымадым, надан қалдым, дирерсән [Насыйри, 1881, б. 3]. «Истыйляхате җәгърәфия» китабында *-ды* формалы категорик үткән заман *-ган* күрсәткечле нәтиҗәле үткән заман мәгънәсендә кулланыла: Җәғрәфйа ғоләмасы ошбу фәндә күп китаплар тәсныйф қыйлдылар. Бәс җәғрәфйа китабларына нәзар салыб, ...җиһан сәйәхләре кебек, бер сулуда бөтен җиһанны сәйәр вә тамаша қыйлалар [Насыйри, 1890, б. 28]. «Ысулы җәгърәфия кәбир» китабында категорик үткән заман хикәя фигыль шулай ук үзенең синтагматик мәгънәсендә, үткәндә дәвамлы булган эшне белдерә: ...әүwәл башта дүрт-биш төпләп яздым, үз телемезгә килешә торган кәлимәләрне табып, җәғрәфйа истыйләхларын белдердем. ...аққа күчермәс борын қарасын алып-алып уқыдылар һәм телләрендә барәкалла ләфызын иҗра қылдалар, ...мең дә сигез йөз җитмеш өченче йылда башлап, җитмеш җиденче йылларда тәмам қыйлдым [Насыйри, 1899, б. 3]. «Хисаплык» дәреслегендә категорик үткән заман үзенең төп парадигматик, ягъни күрелеп үткән, бер мәртәбә булган, тәмамланган үткәндәге эшне аңлата: ...ошбу китабымызны хисаплық дип атадық, ...үз телемездәге сүзләрне сайладық, сан дидек, бер қағыйдәсен җыю дип әйтдек, икенче қағыйдәсен аеру дип атадық, ...өченче қағыйдәсенә суғу дип исем бирдек [Насыйри, 1899, б. 7]. «Ләһҗәи татари» хезмәтендә шулай ук синтагматик мәгънәнең дәвамлылыкны белдерә торган төсмере файдаланыла: ...татар телемезгә хезмәтче мән булаем дип утыз биш йыл уздырдым, ләкин күп мәғнә чықмады. Төн-көн ниқадәр иҗтиһат қыйлсам, шулқадәр җәфа чикдем, милләтемез халқын татар тәсмийә қыйлсам, йаратмадылар, татар теле дисәм, йаратмадылар. «Истыйляхате гыйльме һәндәсә»дә (1895): Имди ошбу тәҗрибәмдән хис қыйлынмыш мәнфәғатькә сөрүрән бу дәфгә һәндәсә фәнендә қыйлләте бизғатемдән катғы нәзар бер китаб йазмаға мөбадәрәт қыйлдым... [Насыйри, 1895, б. 24].

Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, К. Насыйриның фәнни хезмәтләрендә, дөресрәге аларның сүз башында, автор теге яки бу фән хакында ничек итеп материал туплавы, тәҗрибә булдыруы, укытуы һәм менә китап итеп бастырып чыгаруга керешүе хакында мәгълүмат бирә, бу очракта билгеле үткән заман үзенең кабатлаулы, дәвамлы эшне белдерә торган синтагматик мәгънәсе белән ешрак кабатлана. К. Насыйриның «Әнмүзәҗ» (1895) хезмәтендә үткән заман (мазый) фигыленең берлек һәм күплектәге зат-сандагы язылышы бирелә: يازدم – йаздым, يازدق – йаздық, يازدنك – йаздың, يازدنكز – йаздыңыз,

يازدى – йазды, يازديلار – йаздылар [Насыйри, 1975, б. 72-73]. Күренгәнчә, кушымча сузыксыз языла. Әлеге кагыйдә аның әсәрләрндә дә төгәл үтәлә. Мәсәлән, «Әбүгалисина кыйссасы»нда (1889) категорик үткән заман хикәя фигыль I һәм II зат берлек һәм күплек санда, эзлекле рәвештә, *-ды* кушымчасы сузыксыз языла: шөруғ кыйлдым (قيلدم) [Насыйри, 1889, б. 3], исем ққуйдым (قويدم) [Насыйри, 1889, б. 3], бардым (باردم), қайтдым (قاتديم) [Насыйри, 1889, б. 10] һ.б. Берничә урында I зат күплектә *-ды* кушымчасының دو- варианты кулланыла: килдек (كيلدوك) [Насыйри, 1889, б. 8], қайтдық (قايتدوق) [Насыйри, 1889, б. 14] һ.б.

К. Насыйриның гарәп һәм госманлы телләреннән сәнгатьле-дидактик прозаны тәрҗемә кылудагы үзенчәлеге, фәнни хезмәтләрен язудагы тәҗрибә-үрнәге алга таба да дәвам итәлә. Г. Фәезханов «Тутыйнамә китабы» әсәренең ни өчен язылуын (1887) болай аңлата: «Қазан вилайәтемездәге қулланыла торган Тутый намә китабын ғосманлы төрекләре телендә күреб wә ул телне безнең халқымызға аңлаwы мөшкел булғандықдан һәммә дәрд әһәле уқыб файдалансынлар өчен, мәзкүр ғосманлы төрекләре телендән үз татар телемезгә тәрҗемә қыйлдым» [Фәизхан, 1896, б. 2]. Монда К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»н (1881) ни өчен тәрҗемә кылуы хакындагы фикере кабатлана [Насыйри, 1898, б. 3].

Мәгълүм булганча, «Тутыйнамә китабы»нда (1887) бара торган вакыйга-хәлләрне хикәяләү дә «Әбүгалисина кыйссасы» ысулынча башкарыла, ягъни риваять сөйләүчеләрнең сүзләре кабатлана: ...Әһле хикәйәтдән шул рәвешле ривайәть ителер ки, ...дип башлана да, *-ды* формалы фигыльләр белән дәвам итәлә: ..көнләрдә бер көн әүлийәләр зийарәтендән бер қабернең зийарәтенә барып, бала өчен доға қыйлды вә доғасы хода дәргәһында қабул булды. Бер көн бу хуҗа Сәғыйднең өенә бер газиз қарт килеп, мөсафир булды wә диде ки, ...туғыз ай ун көн булғанда, бер ир бала дөньйаға килде... [Фәизхан, 1896, б. 3] һ.б.

Аңлашылганча, бу төрдәге хикәяләүдә *-ды* формасы, нигездә, *-а, -ган, -а иде, -а торган ид*е һ.б. формаларның инварианты буларак кулланыла; бу мәгънәсендә *-ды* күрсәткечле хикәя фигыльнең III заты актив була. Г. Фәезханның «Тутыйнамә китабы»нда, нигездә, *-ды* кушымчасы сузыксыз варианты белән языла: тәрҗемә қыйлдым (قيلدم) [Фәизхан, 1896, б. 2], уғыл теләдем (تلادم) [Фәизхан, 1896, б. 3], уйнап әйтдем (ايتدم) [Фәизхан, 1896, б. 4] һ.б. Автор «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» (1887) хезмәтендә бу язылышны кагыйдә итеп бирә [Фәизхан, 1887, б. 19–20].

I зат берлек яки күплек сан формасында авторның үз исеменнән сөйләү алымы фәнни-нәзари, дини-дидактик һәм гамәли-публицистик әсәрләрне язганда төп нигез булу белән бергә, XIX гасыр ахырында сәнгатьле проза әсәрләрен иҗат иткәндә дә файдаланыла башлый. Әлеге ысул белән М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» (1886) романы язылa. Аннан соң З. Бигиев, Ф. Кәрими, Р. Фәхретдин, Г. Гафуров-Чыгтай, З. Һади, Ш. Мөхәммәдев һ.б. мәгърифәтче әдипләр сәнгатьле чәчмә әсәрләрен, һәр автор үзенә генә хас үзенчәлекләр белән, шушы ук стильдә иҗат итә [Бәширова, 1979, б. 16–41].

Әсәрендә бара торган вакыйга-хәлләрне, вәзир һ.б. әйтте дип түгел, авторның үз исеменнән сөйләп хикәяли башлавы, төрки-татар әдәбиятында эстетик эчтәлекне формалаштыра торган сәнгатьчә чаралардан файдалануның яңа этабы булып таныла: «...Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев ...болар әдәбияте нәфисәнең беренче сандугачларыдыр», – дип белдерелә [Ибраһимов, 1987, б. 209]. Әлеге дәвердә, автор үзе сөйләп хикәяли башлагач, татар әдәбиятында Ә. Уразаев-Кормаши, К. Насыйри, Г. Фәезханов, һ.б. тәрҗемә әсәрләрендә ныгыган, вакыйганы риваять тапшыручылар яки акыллы кешеләр сөйләме итеп бирә торган штамп җимерелә. Реаль автор, әсәрдә сөйләнәчәк хәлләрнең кайда, кайчан, нинди җирлектә баруын тәгаенләп сүзен башлый: Идел нәһерендән озақ дәгел бер татар аwылы мәүҗеддер. ...хикәйәмези йөңел аңлатмақ өчен, адыны «Н» хәрефе илә ишарә итәмез, ...аwылында ике мәсҗед вар... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 45]. Автор укучысына эндәшеп, вакыйганы үз исеменнән алып бара, ачыктан-ачык үзенең мөнәсәбәтен белдерә (...әмма қыйссаның асылындан бераз аерылып китдем, гафу итеңез...), шулай итеп, «зат»лы һәм «җан»лы сөйләм барлыкка килә, тел чаралары, шул исәптән фигыльләрдән файдалану, әлеге үзенчәлеккә җайлаштырыла. Укучыга эндәшеп сөйләгәндә, вакыйгалар аның күз алдында – менә хәзер бара сыман тоела, фигыльләрнең дә хәзерге заманда булуы таләп ителә. Риваять сөйләүчеләрнең сүзен укучыга җиткерүдә төп чара булган *-ды* күрсәткечле үткән заман хикәя фигыль вакыйганы алып баруда үзенең урынын хәзерге заман фигыль формаларына тапшыра, шул ук вакытта категорик үткән заманның һәм вакыт, һәм модальлек белдерү мөмкинлеге җанлы сөйләмдәгечә табигыйлек ала: ...Тафсири қуйды. Бүлмәсендә гизәйүр. Йөзендән дәрин фикрә далдыгы беленүр. Гизгәндә биек буен wә ийү қыйәфәтене күрсәң ғашыйқ улурсән [Акъегет, 1886, б. 4]. Китерелгән өзектән күренгәнчә, үткән заман хикәя фигыль

үзенең төп-парадигматик мәгънәсендә, ягъни кабатланмаган, тәмамланган, сөйләү моментына кадәр булган, сөйләүче күреп-белеп торган эшне белдерә. *-ды* формасы эзлекле булып дәвам ителми, аңардан соң ук хәзерге, аннан киләчәк заман формалары кулланыла, гадәти, табигый сөйләм барлыкка килә. Әлеге әсәрдә билгеле үткән заман парадигматик мәгънәсе белән дә, синтагматик мәгънәсе белән дә файдаланыла: ...бу кичә менла пәк рәхәтсез кичерде, чөнки җаwаб улырмы, я улмазмы... [Акъегет, 1886, б. 25]; Бу өч дуст сүзләшә-сүзләшә чуқ wақыт утырдылар... [Акъегет, 1886, б. 32]; Ғыйшық ләззәтилә ләззәтләнеб, йегет wә қыз үбешеб-қочышыб, бер-беренә яқын чәкелделәр [Акъегет, 1886, б. 39]. Әлеге мисалларда категорик үткән заман эзлекле, дәвамлы, кабатлаулы эшне белдерә. Сирәк кенә *-ды* кушымчалы билгеле үткән заман нәтиҗәле үткән заман урынында килә: ...менла кәзалик йуқ, мәктүбе алынмаган: кәлмәде, кәлмәде, һәлақмы улам икән [Акъегет, 1886, б. 56] һ.б.

Шуның белән бергә, М. Акъегетнең әлеге әсәрендә категорик үткән заманны куллануда, «Әбүгалисина кыйссасы»н хикәяләүдә актив булган үзенчәлек тә дәвам итәлә: иярчен кушма җөмләнең баш җөмләсендә хәбәр, гадәттә, *-ды* формалы фигыль белән бирелә, бу типтагы җөмләләр «Хисаметдин менла» әсәренең дә көен-ритмын барлыкка китерүдә катнаша: Атны сарай астына йирләшдергән заманда, менланың күзенә гүзәл бер күренеш раст кәлде: йорт буенча бақчадан арт ханәйә бер қыз кәчәйүр [Акъегет, 1886, б. 9]; Күрде ки, ханәдә диванлар wә өстәлләрдә хили халық-төҗҗар wә ғаwам утырмыш [Акъегет, 1886, б. 10]. К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»ннан аермалы буларак, бу төрдәге җөмләләрнең бирелешендә ныклы калып саклана дип әйтеп булмый. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» (1886) әсәрендә исә *-ды* күрсәткече I һәм II зат кушымчалары алганда, рәттән сузык белән языла: آلدوم – алдым, قایغولندوم – қайғыландым [Акъегет, 1886, б. 6], قوشدونكز – куштыңыз [Акъегет, 1886, б. 8], قورتولدوك – кортылдың [Акъегет, 1886, б. 13] һ.б. Шул ук вакытта اكلادكز – аңладыгыз сүзе сузыксыз язылган [Акъегет, 1886, б. 20].

Мәгърифәтче әдипләр әсәрләрен вакыйганы сөйләп бирү ысулында язсалар да, тема һәм сюжет корылышының төрлелеге сүз сайланышына, җөмләләрнең төзелешенә, димәк фигыль формаларының кулланылышына үзенчәлекле йогынты ясый.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887) романы да, турыдан-туры авторның мөнәсәбәтен белдереп, вакыйга барачак

урынны күрсәтеп башлана: Хикәйәмез бер ғаҗәеб гүзәл хикәйәдер. Хикәйәмези яхшы аңлатмақ өчен, әүwәлән воқуғасы нә йирдә вә нә wақытда улдығыны йазамыз [Бигиев, 1887, б. 2; Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 88]. Бу әсәрдә *-ды* кушымчалы билгеле үткән заман хикәя фигыль тема һәм сюжет төзелешенә кирәк булган вазифа үтәп, эзлекле рәвештә, билгеле бер төгәл вакыт арасында эшләнгән эшне белдерә: «Бу үткән кичдә бу мәктүлә хатынға кем булса кәлдеме? ...Нә wақытда кәлеп, нә wақытда кәтде?» – дәйү сөаль қылдуқларында, швецар: «Ахшам сәкез сәғатьдә кәлеп, унике сәғатьдә китде», – дәйү җаwап вирде. «...Қач сәғать? – дәйү бәндән сөаль қыйлды, бән, сәғатькә қарап, унике сәғать – дәйү җаwап вирдем...» [Бигиев, 1887, б. 3]. З. Бигиевның «Гөнаһе кәбаир» (1890) романында да, нигездә, шушы ук хәл, ягъни билгеле үткән заман вакыт төшенчәсен тәгаенлый торган сүзләр ешрак кулланыла: Бөйләчә сөйләшеп, унбиш-йикерме дәқыйқа эчендә йимәк wә эчмәк тәмам улғач, мөсафирләремез, сәдақаләрен виреп, имам әфәнде өендән кәтделәр [Бигиев, 1890, б. 5; Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 141]. ...Бөйләчә қарт хәзрәтнең ...нәсыйхәтләре тәмам улдығы wақыт ат-ғарәбә дә тәмам wә хәзер улды, ...йаздығымыз мөәзинлә бәрабәр ...йула чықдылар [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 143] һ.б. Бу типтагы җөмләләр рәттән диярлек тезелеп бара, димәк, З. Бигиевның ике әсәрендә дә, нигездә, билгеле үткән заман хикәя фигыль белдерә торган эш-хәлнең вакыты тагын өстәмә рәвештә тәгаенләнә, аның дәвамлылыгы аңлатыла, синтагматик мәгънәсе активлаша.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында (1890) категорик үткән заман хикәя фигыльнең *-ды* кушымчасы I һәм II зат берлек һәм күплектә сузыклы һәм сузыксыз вариантларда чиратлашып кулланыла: قالدوق – қалдық [Бигиев, 1890, б. 5], ويردوك – вирдек [Бигиев, 1890, б. 13], ايتدوم – әйтдем [Бигиев, 1890, б. 16], قيلدنك – кыйлдың [Бигиев, 1890, б. 16] һ.б.

Ф. Кәрими һәм Р. Фәхретдин әсәрләренең сюжеты, үлгән кешене эзләүгә корылмаганга, категорик үткән заман фигыле белдерә торган эшне тагын өстәмә рәвештә сәгатьләп-минутлап тәгаенләргә кирәкми, монда алар, башлыча, бер-бер артлы эзлекле булып бара торган эш-хәлләрне белдерү вазифасы белән кулланыла. «Салих бабайның өйләнүе» (1897) әсәрендә: ...Айлар, йыллар үтде, без дә бераз үсдек, ...бер заман китдек-китдек, бара торғач, бер аwылға барып җитдек,... әстәғфирулла, йалғыш әйтдем, барып җитдек түгел, тик аwылға якынлашмаға башладық [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 223].

«Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» (1898) хикәясендә: ...таеп йыгылып қайнап тора торған бер самоварға бәрелде, самовар мәхдүмнең өстенә ауды, мәхдүмнең бәгзе җирләре пеште, берничә көнләр хәстә тотты... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 234]. «Бер шәкерт илә бер студент» хикәясендә (1900): ...Пароход Лаешқа килеп житде. Бәгзеләр керделәр, бәгзеләр чықдылар. Күп тормады – кузғалып китде, мин юғарыда бер утырғычқа утырдым [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 251]. Фигыльләрнең бу рәвешле кулланылышы әсәрнең ритм-көен барлыкка китерә. Нигездә, хәзерге заман фигыле белән хикәяләнә торган сәяхәтләрдә дә, урыны-урыны белән әлеге тәртип дәвам ителә: Өченче ишарәт вирелде, wә жиде сәғәт қырық дәқыйқадә поезд хәрәкәт итде. Озатмаға кәлгән адәмләрең әл wә мәндил ишарәтләре чуға вармады, күренмәз улды. ...қара қаршыға утырдық, нияз вә тәзарығ итдек, бер-беремезне хәерләдек. Сүз киселде... [Кәрими, 1996, б. 152-153] һ.б. Бу авторның сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә дә, сәяхәтнамәләрендә дә, *-ды* кушымчасы зат-сан төрләнешендә, сузыксыз языла: باراخودينه كردم – пароходына кердем, اوطردم – утырдым, باشلادم – башладым, ايسابلادم – исәпләдем [Кәрими, 1900, б. 2-3] һ.б., آله خق اولدم – алачақ улдым, حاضرلدق – хәзерләдек, آلدق – алдық, بيلدك – белдек [Кәрими, 1902, б. 5] һ.б.

Р. Фәхретдиннең сәнгатьле прозасында категорик үткән заман хикәя фигыльнең әлеге вазифасы, ягъни эш-хәрәкәтнең бер-бер артлы эзлеклелеген белдерүе, тагын да сиземлерәк булып, әсәрнең билгеле бер ритмда баруын хасил итә. «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә (1899): Бу мөбәрәк сүзләрнең та хәрефләренә қадәр ядыма алып дыңладым, қулыны тотып үпдем, тәқать китерә алмый йығладым, хәсрәт илә шатлықны җыйған хәлемдә аерылдым, вәғазьләре илә ғамәл идәргә гаһедләр итдем... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268]. «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә (1903): Муса ақчасыны андан қарады, бондан эзләде, сорады, йалынды, ағлады, йуқ, табылмады. ...бу эшдән асла хәбәрдәр дәгел идегене сөйләде, боның үзәренә эш дә тәфтишчегә бирелде, Муса да хибес улынды [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 322].

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» романында (1899) *-ды* күрсәткечле хикәя фигыль I һәм II зат кушымчалары алганда, нигездә, сузыксыз гына языла: تودردم – тудырдым [Фәхретдин, 1899, б. 5], اوستردم – үстердем [Фәхретдин, 1899, б. 5], آڭلامادیلر – аңламадылар [Фәхретдин, 1899, б. 6], بيلماديلر – белмәделәр [Фәхретдин, 1899, б. 6], تابشردم – табшырдым [Фәхретдин, 1899, б. 6] һ.б.

Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» (1888) драмасында *-ды* кушымчасы сузыклы варианты белән языла: клиндер алдым (آلدوم) [Хәлиди, 1888. б. 5], исемене белдем (بلدوم) [Хәлиди, 1888. б. 7], хуш килдеңез (كيلدكنوز) [Хәлиди, 1888. б. 9]; бер-ике урында сузыксыз язылу очрагы да бар: Аллаға тапшырдық (طاپشردق) [Хәлиди, 1888. б. 6], كوردم – күрдем, [Хәлиди, 1888. б. 7] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, *-ды* кушымчалы фигыль зат-сан кушымчалары алганда, сузыкны саклап яисә сакламыйча файдаланылуы ниндидер системага нигезләнә дип әйтеп булмый, сузыксыз вариант ешрак кабатлана.

Классик әдипләр иҗатларын башлаганда ук, вакыйганы алып бара торган хикәяләүдә автор сөйләменең, авторның үз исеменнән генә булмаска кирәклегенә игътибар итәләр. Г. Исхакый «Кәләпүшче кыз» (1900) хикәясенең керешендә: «...Һәр язылган сүз үз вакыйгаларын тасвир, үз хәлләрен бәян улмаз! Хосусан, мөхәрирләр, шагыйрьләр ни язсалар, кемне тасвир кылмакчы булсалар, шуп кеше булып сөйләрләр һәм сөйләтерләр...», – дип, әдәби әсәрдә укучы күрә алырлык тасвир булырга тиешлеген ассызыклап, иҗат эшенең максаты билгеләнә [Исхакый, 1998, б. 50]. Алга таба бу мәсьәләне: «Монда очрый торган мин кәлимәсен мөхәррирнең үзеннән тәгъбир дип уйлау хата булачакдыр. Хикәя язганда бу тәгъбир, гомум тарафыннан кабул ителгән бер тәгъбир булып, мөхәррирнең үз фикерен күбрәк кертер өчен истигъмаль ителәдер», – дип, Ф. Әмирхан тәфсилләп аңлата [Татар әдәбияты, 1984, б. 57]. Шулай итеп, гасырлар буена килә торган «күрү ноктасы» катлауланырга, ягъни хикәяләү, авторның үз исеменнән генә бармаска тиешлеге нәзари нигездә көн тәртибенә куела. Әмма гамәли яктан караганда, авторның үз исеменнән генә булмаган хикәяләү ничек барырга тиешлеген һәр автор үзе эзли, төрле авторда төрле эзлеклектә гамәлгә куела башлый, авторның персонажларына, аның «кешелегенә» һәм аңа карата авторның нинди мөнәсәбәттә булуына нигезләнеп, төрле әсәрдә төрлечә яңгыраш ала, автор образы дигән төшенчә формалаша.Әлеге үзенчәлек эш-хәлләрнең булып үтүен белдерә торган билгеле үткән заман хикәя фигыльләрнең кулланылышына да үзенчә тәэсир итә, мәгърифәтчеләр иҗатының дәвамы булып килә торган алымнарның үзгәрешен китереп чыгара. Дөрес, аларның беренче хикәяләрендә әле бу үзгәреш нык сизелми, ягъни алар, хикәяләү, персонаж исеменнән бирелгәндә дә, авторның үз карашы, үз сөйләме буларак кына дәвам итеlә. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт...» (1899) хикәясендә: ...этине дә игә китерделәр, мәдрәсәгә дә килдем,

бигрәк бәхетлелектән (Дарелтәдрис) мәктәбенә кабул иттеләр, ...бөтен халыҡтан тәбрик иттерде, ...бер көмеш сәғать бирелде [Исхакый, 1998, б. 43]. Шуның белән бергә, хикәяләүдә авторның үз сөйләмен алып бара торган *-ды* кушымчалы фигыльнең эзлеклелеге дәвам итсә дә, башка формалар белән аралаштырыла, нәтиҗәдә персонаж җанлана башлый: портреты, уй-теләкләре, тышкы кыяфәте, шөгыле һ.б. күз алдына бастырыла. Шушы ук ысулда «Капитан кызы» тәрҗемә ителә (1902). «Очрашу яки Гөлгыйзар» хикәясендә (1902) инде персонаж тәмам яши башлый. Хикәяләү авторның үз исеменнән башлана, әмма аерым персонажның башыннан үткән хәлләрен сөйләве буларак дәвам ителә, бу сөйләмгә икенче персонажның башыннан үткән хәлләрен сөйләве кушыла, нәтиҗәдә *-ды* кушымчалы фигыльнең сөйләү моментыннан алда бер тапкыр булган, тәмамланган, сөйләүчегә билгеле булган эш-хәлләрне белдерә торган парадигматик мәгънәсен куллану бик урынлы була. Бу мәгънә сүз җаенда дәвам ителә торган эш-хәлләрне белдерә торган синтагматик мәгънәсе белән бергә кушылып китә: ...анда кердем. Анда уқыдым, Фикерләр башланды, ...беленә башлады, ...исламиятқә артыҡ файда юқдығыны белдем, ...төрле китапларыны уқыдым... [Исхакый, 1998, б. 79]. Сөйләме белән бергә, персонажның характерын, теләк-омтылышларын һ.б.ны тасвирларга омтылыш ясала. Г. Исхакыйның «Бай угылы» (1903) әсәрендә *-ды* кушымчалы категорик үткән заман хикәя фигыльләр эш яки хәлнең бер-бер артлы алмашынып торуын күрсәтү өчен файдаланыла: ...мәдрәсәгә өшкерергә чәйнек кертделәр, шәкердләрдән өшкертеп алдылар, үзләре дә өшкереп, бикәнең өстенә шул суны сиптеләр, йөзләренә бөркеделәр. Бикә азрақ хәл алған кеби булды, күзене ачды, қаранды, менә озақ үтмәде, кисү башланды... [Исхакый, 1998, б. 110]. I һәм II зат белдерелгәндә *-ды* кушымчасы сузыксыз языла: استەدم – эстәдем, اويالمادڭ – оялмадың, صورادق – сорадыҡ [Исхакый, 1910, б. 165], آلدڭ – алдың [Исхакый, 1910, б. 170], بتردڭ – бетердең [Исхакый, 1910, б. 195] һ.б.

Г. Исхакыйның әсәрләрендә I һәм II зат кушымчасы алган үткән заман фигыле сузыксыз языла: ييتدم – йитдем [Исхакый, 1904, б. 3], باشلامادق – башламадыҡ [Исхакый, 1904, б. 11], ياتدق –ятдыҡ [Исхакый, 1904, б. 11], ايشتدم – ишетдем [Исхакый, 1904, б. 29], بولدڭز – булдыңыз [Исхакый, 1904, б. 29] һ.б.

Эш яки хәлнең бер-бер артлы алмашынуын белдерә торган *-ды* кушымчалы фигыльләрне куллану Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал һ.б. әсәрләрендә дә дәвам ителә. Мәгърифәтчеләрдән килә тор-

ган бу традиция классик әдипләрнең әсәрләрендә төрлечә төзелгән җөмләләр белән бирелә, шуңа күрә катгый штамп булып күренми, һәр әсәрнең үз ритмы таләп итә торган көйгә җайлаштырыла.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) хикәясендә *-ды* кушымчалы билгеле үткән заман фигыльләрен куллану мәгърифәтчеләр иҗатыннан әллә ни аерыла дип әйтеп булмый. Әмма *-ды* кушымчалы фигыльләрне әсәр өчен кирәк булган интонация барлыкка китерерлек итеп яраштыра алуга әдип шактый тиз ирешә. «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә» (1909) хикәясендә: ...Заманның мәдәнийәте белән вөҗүдкә килгән ғали биналар йанында садә wә иске манараның торуындан килгән манзара гүйә халь теле белән аңа әйткән кеби тоелды. Инде татар қартайды, аның дәwере үтте. Аның урынын йәшь хәйатлы икенчеләр алды... Бу табиғый... Мин ничек иске wә беткән булсам, татар да шуның кеби хәлсез wә беткәндер... [Ибраһимов, 1974, б. 477]. Аңлашылганча, билгеле һәм нәтиҗәле үткән заманнарның чиратлашуы әйтелергә тиеш фикерне табигый-җанлы ясый. «Татар хатыныниләр күрми» повестенда әлеге фигыль белән бирелә торган җөмләләр рәттән тезелеп, ашкынулы бер агым барлыкка китерә: Җәйге кыска төн гаҗәп тиз үтеп китде. ...Қараса, йерақтан, тау, урман артыннан, әле чақ қына сызылып, алсу таң атып килә. Хатын қаушап китте. Ирен уйатмасқа тырышып, аяғына оеқ-чабатасын киде, тиз генә чәчен ипләп, битен юды да, морҗа ачып, мичен якты. Йарый, утыны кичтән кертелгән иде. Аннан соң кичә иләгән җилпучлы оны белән икмәген басты, аны, чикмән белән қаплап, җылырақ урынга утыртты... [Ибраһимов, 1974, б. 325] һ.б. Вакыйгаларның тиз алышуын, эзлекле үсешен белдерә торган билгеле үткән заман, тасвирның персонаж карашыннан баруын күрсәтә, әлеге сурәтне ассызыклау өчен, бер мәртәбә хәзерге заман фигыле кулланыла.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» (1907) хикәясендә: Йаңадан бер звонок булды. Концерт биреләчәк биегрәк урында сақал-мыеқларын қырган, йегерме биш яшьләрендә матур гына бер йегет күренде. Моның чығуы белән, залдағы таwыш та, қайчы белән кисеп төшергән кебек, бердән туқтады. ...Беренче фасыл тәмам булды. Һәркем урыныннан кузғалды, йөрде, китде, килде... [Әмирхан, 1984, б. 19]. «Бәйрәмнәр» хикәясендә (1908): Вәли абзый өенә қайтды, анда да һәммәсе әүwәлге йеллардағы шикелле үк булдылар. Ғайникамал абыстай хәләл иренең қулыны үбеп күреште. Икесе дә икенче йелларның ғаетләрен шатлық, тигезлек белән күрүне теләштеләр... [Әмирхан, 1984,

б. 19]. «Татар кызы» (1909) хикәясендә: Ул туды... Туғач аны башқаларны – балаларны сала торған бишеккә салдылар; анасы үз күңелендә ир балалары белән җәнәшә үк җирдә аңар урын бирде, ир балалары белән бер дәрәҗәдә үк мәхәббәт итде... [Әмирхан, 1984, б. 42].

Хикәяләү I зат автор исеменнән барса да, персонажның «кешелеге» күз алдына бастырыла. Хикәяләү III заттан барганда, ягъни *-ды* кушымчалы фигыльләр рәттән кулланылганда да, персонажның гүзәллеге, авторның мөнәсәбәте укучы «күреп тора» торган халәттә тасвирлана: ...Ул хатларны җыеп, комодның бер тартмасына салды да, бер нәрсә дә уйламасқа тырышып қына, ялқау ғына чишенергә тотынды һәм, чишенеп, эчке күлмәктән генә калғач, көзге алдына барып, толымнарын сүтте дә қуе, озын, тәртипсез, ләкин матур таркалган чәчләрен ал яққа, күкрәге өстенә чығарып қуйды һәм, көзгедән қарап, үз сурәтеннән үзе кәефләнде...» [Әмирхан, 1912, б. 32].

Әлеге мисалларның, аерым әсәрләрдән алынган кыска гына өзекләр булуга карамастан, һәрберсе үзенә генә хас төзелештә, ягъни үзенә генә хас ритм-көй белән яңгыравы сиземләнә: *-ды* кушымчалы категорик үткән заман фигыльләр һәр әсәрдә шул әсәр эчтәлеге генә таләп итә торган интонациягә җайлаштырыла. Әлеге интонацияне, асылда, хикәяләүнең кайсы заттан баруына карап, фигыльләрнең шул төрдәге зат кушымчаларының кабатлануы барлыкка китерә. «Кадерле минутлар» (1912) хикәясендә: بولدق – булдық [Әмирхан, 1912, б. 6], كوتەردك– күтәрдек [Әмирхан, 1912, б. 7], كشردك – керешдек [Әмирхан, 1912, б. 7], طرودق– тордық [Әмирхан, 1912, б. 9] һ.б. Башка авторлардагы кебек үк, *-ды* кушымчасына зат күрсәткече кушылганда, сузык язылмый.

Драма жанрындагы әсәрләрнең текстларында, җанлы диалогик сөйләмдәге кебек, *-ды* формалы үткән заман хикәя фигыльнең төп парадигматик мәгънәсе ешрак файдаланыла: «...мин сиңа бер эш ясыйм» дип бернәрсә өшкереп бирде. Андан соң бер доға бирде. Мин шулай эшләдем Хабибә абыстайға бер оч киндер дә бирдем. Үзем теләгәнгә биреп қуйдылар. Қул белән қойған кебек булды («Бичара кыз»). ...Атасы дәшеп алды, исемен дә шунда белдем. Асылбикә абыстай йибәрде, сәлам әйтде, йәнә әйтде. Әлифә бикә янындан төшдем, Әлифә бикә бик җаратды («Рәдде бичара кыз») һ.б.

Башка жанрлардагы кебек үк, драма әсәрләрендә дә, үткән заман хикәя фигыльнең без өйрәнә торган формасы үзенең беренче синтагматик мәгънәсе белән дә файдаланыла: а) тәмамланмаган эш-хәлне

белдерә: Йөдәдем инде бу йүтәл белән, дару да итеп ҡарадым, бер дә файдасы булмады («Бичара кыз»); ә) берничә мәртәбә кабатлаулы эш-хәлне белдерә: Йаучы булып ике мәртәбә килде. Без фәқыйрь булдық, йәтим булдық – уқый алмадық, имди Яқуб бай, бай булды, бер уғылыны уқытмый ҡалдырды («Морад Сәлимов»). Ух калмады кычкыра-кычкыра тамагым («Бичара кыз») һ.б.

Икенче синтагматик, ягъни күчерелмә мәгънәләре, гадәттә, сөйләм моменты белән бәйле булган эш-хәлне белдерүгә нисбәтән бирелә: – Бәбкәм ҡай төшең аwырды? («Бичара кыз»). – Хуш килдеңез, бай, түргә узыңыз урындан. Денщик аҡчаны алып, чығып китде. Генерал, сәғатене ачып, минутҡа ҡарап, әйтә: басҡычтан төшде, урамға чыкды, консул йортыны узды, күперне чыкды, тауға менде, аҡчаны ҡайтарып алды, ...ун минутта булды («Морад Сәлимов») һ.б.

Дини әдәбиятта, балалар әдәбиятындагы кебек үк, *-ды* формалы үткән заман хикәя фигыль вакытка бәйле булмаган мәгънәдә кулланыла: ...Мөхәммәд ғаләйһиәссәлам Мәккә халыҡларыны мөселман булырга өнди башлағач, берничә йөз кеше иман китереп, Ислам динене ҡабул итделәр. Башҡалары – һәрберсе дошман булып, Мөхәммәд ғаләйһиәссәламгә төрле җәбер wә җәфалар ҡыйлырға тырышдылар. Хәтта берничә мәртәбә үтермәкче дә булдыдар. Аллаһы тәгалә ...саҡлады. Мәккә кяфирләре аңа артыҡ зарар вә зыян ҡыйла алмадылар. Ахырда Мәккәдә 13 йыл пәйғамбәренә күчде... («Гыйбадәте исламия») һ.б.

Фәнни хезмәтләрдә, әйтелеп үтелгәнчә, I зат берлек һәм күплектәге билгеле үткән заман алга чыга, аның бер мәртәбә булган-тәмамланган һәм дәвам ителеп кабатланган, яисә билгеле бер вакыт яки урын белән чикләнгән мәгънәләре активлаша: ...Бу китабны, мәмләкәтемезгә руслар кергәнче һәм алар хакимлеге астына кереп ҡалғандан соң булған ике төрле хәлдән чығып, ике бүлек итеп тәртип итдек («Мостафа әл-әхбәр фи әхвәли Казан вә Болгар»). ...Без бу китапны ибтида ҡыйлдық, дәхи Шәҗәрә төрек дип исем ҡыйлдық, туқыз баба үзәренә бүлдек («Тарих шәҗәрәи төрек»).

Т. Яхинның «Сабый вә сабыялар өчен мәргүб булган хикәяләр вә мәкальләр» (1897) җыентыгында: «Әмма бәғад...безнең дин ҡардәшләремез арасында сабый wә сабыяларға фи әлҗөмлә төрки белә башлаганчы да уқыр өчен, хикәйәләр аз улдығындан, ошбу хикәйәләрне тәртиб ҡыйлдым ...уқый-уқый төрки китапларын таза белә башларлар...» – дигән максат белән махсус сайланып алынган хикәяләрнең текстларында, категорик үткән заманның *-ды* кушым-

часы, зат төрләндергечләре алган вакытта, сузыксыз варианты белән языла: үгез кадәрле булдымты (بولدمطی) [Яхин, 1902, б. 4], файда күрмәдем (كورمادم) [Яхин, 1902, б. 6], файда китердем (كيتردم) [Яхин, 1902, б. 7] һ.б. С. Рахмәнколыйның «Монтазам кыйраәт китабы»нда (1912) да шушы ук тәртиптәге язылыш күзәтелә: طابمادڭ – тапмадың [Рахмәнколый, 1902, б. 4], بولا آلدڭ – була алдың [Рахмәнколый, 1902, б. 5], اوتكاردم – үткәрдем [Рахмәнколый, 1902, б. 6] һ.б. Бу хезмәтләрнең барысында да кушымчада сузык күрсәтелми. М. Өметбаевның «Татар нәхүсенең мохтәсары» хезмәтендә бу язылыш кагыйдә итеп бирелә [Өметбаев, 1901, б. 26]. Алга таба языла торган фәнни хезмәтләрдә (мәсәлән, Җ. Вәлидинең «Татар әдәбиятының барышы» (1912), Һ. Атласиның «Сөен-бикә» (1914) китабында) *-ды* кушымчасы, зат төрләндергечләре алганда, сузыксыз вариантта языла.

Шулай итеп, категорик үткән заман хикәя фигыль төрле жанр-стильләрдә, шул стильнең таләбе белән, үзенең төрле мәгънәләре белән кулланыла; I һәм II зат төрләндергечләре алган вакытта, берлек һәм күплек санда, барлык һәм юклык төрендә *-ды* кушымчасы төрле жанр-стильдәге текстларда, нигездә, сузыксыз вариантта языла, үз вакытында төзелгән сарыф-нәхү дәреслекләрендә әлеге язылыш норма итеп күрсәтелә. *-ды* (دی-) формасы III зат берлектә дә, күплек санда да йай (ی) сузыгы белән языла: باردی – барды, كيلدی – килде, باردیلار – бардылар һ.б. Зат белән төрләнгәндә кыскартылган кушымчаларны ала, гомумтюркологик тикшеренүләрдә, бу күрсәткечләрне исемнәрнең тартым кушымчасына туры килә дип аңлаталар [Сравнительно-историческая..., 1988, б. 375].

Әлеге фигыльнең хәзерге татар телендә әдәби норма буларак кулланыла торган вариантлары Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) дигән хезмәтендә бирелә [Алпаров, 1945, б. 91].

*Кыскача нәтиҗәләр. -ды* күрсәткечле үткән заман хикәя фигыль XIX гасыр – XX йөз башында төрле жанр-стильдә язылган текстларда актив-эзлекле кулланыла, әмма аның төп-парадигматик һәм контекстуаль-синтагматик мәгънәләре, ягъни аспектуаль һәм модаль мөмкинлекләре төрле текстта төрлечә реальләшә.

Кеше сүзен сөйләү рәвешендә хикәяләнә торган К. Насыйри һәм Г. Фәезхановның тәрҗемә әсәрләрендә *-ды* формасы әсәрдә бара торган вакыйганы алып баруда төп чара булып тора, әмма бу әсәрләрдә әлеге форманың темпораль мәгънәсе дә, аспектуаль һәм модаль мөмкинлеге дә табигый халәтендә тулаем реальләшә дип әйтеп булмый,

чөнки *-ды* формасын бу очракта үткән заманның башка формалары яисә хәзерге заман күрсәткече белән дә алмаштырып кую мәгънәгә зыян китерми; әлеге текстларда *-ды* күрсәткечле үткән заман хикәя фигыльнең, билгеле бер дәрәҗәдә, модальлеге хәрәкәткә китерелгән «инвариант заман» була алу мөмкинлеге эшкә җигелә.

Авторның үз исеменнән языла торган фәнни хезмәтләрдә, сәяхәтнамә һәм сәнгатьле чәчмә әсәрләрдә вакыйга-хәлләрне алып баруда төп көч булып хәзерге заман фигыль формалары күтәрелә, шуның белән бергә, категорик үткән заманның һәм вакыт, һәм модальлек белдерү мөмкинлеге җанлы сөйләмдәгечә табигыйлек ала, төрле әдипнең төрле әсәрендә *-ды* күрсәткечле үткән заман хикәя фигыльнең төрле мәгънәсе төрлечә активлык белән файдаланыла.

Классик шагыйрь һәм әдипләр иҗатының башлангыч чорында ук, автор сөйләме дигән төшенчәне, автор образы дип аңларга кирәклек көн тәртибенә куела башлагач, әлеге фигыль формасын куллану һәр авторның үз язу ысулына яраклаштырыла: әсәрнең ритм-көен, образлар системасын барлыкка китерү чарасына әверелдерелә.

Нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль, өйрәнелә торган чорда иҗат ителгән тезмә һәм чәчмә әсәрләрдә, хәзерге әдәби телдән аермалы буларак, *-ган/-кан* күрсәткече белән генә түгел, тагын *-мыш* һәм *-ып* кушымчалары белән дә ясала. Татар теле фән буларак тикшерелә торган беренче грамматикаларда *-мыш* һәм *-ып* кушымчаларына игътибар ителми, *-ган/-кан* күрсәткеченең генә мәгънәсе күрсәтелә.

Г. Фәезханов «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» (1887) хезмәтендә үткән заманның *-ды* күрсәткечле *мазый шөһүди,* ягъни «үткән заманда вакыйгасы рәүшанлык белән кыйлынган бер эшкә дәлаләт булган сыйгалардан» аермалы буларак, *-ган* кушымчалы фигыльне «...мазый нәкъли, ягъни үткән заманда вакыйгасы нәкъли булган бер эшкә дәлаләт кыйлган сыйгаларны әйтәләр..», – дип, аларның I зат берлектә – *-мын/-мен,* күплектә – *-быз/-без,* II зат берлектә – *-сын/-сен,* күплектә – *-сыз/-сез,* III зат берлектә – нуль, күплектә *-лар* кушымчалары ала дип билгеләмә бирә [Фәизхан, 1887, б. 19–20]. Шулай итеп, бу галим татар телендә шаһидләр күреп, алар карап торганда булган, шулай ук эш яки хәлнең булуын күреп түгел, кешедән ишетеп кенә сөйләүне белдерә ала торган (нәкъли) ике төрле үткән заман фигыле булуын ассызыклый, аларның барлык һәм юклык төрләрендәге һәр өч затта нинди кушымчалар алуын күрсәтә, *-ган* аффикслы фигыльнең тулы зат кушымчалары алуы әдәби норма итеп

бирелә, әлеге аффиксның дүрт вариантта *(-ган/-гән, -кан/-кән)* язылуын искәртә.

М. Өметбаевның «Татар нәхүсенең мохтәсары» (1901) дәреслегендә үткән заман фигыле *мазый мотлак шөһүди* һәм *мазый нәкъли* дип бүлеп карала, әмма монда мазый нәкълинең ике дәрәҗәсе бар дип күрсәтелә: мазый нәкълинең беренче дәрәҗәсе мазый кисәге *-ган* кушылып ясала, мазый нәкълинең икенче дәрәҗәсе мазый кисәге *-б* кушылып ясала, һәр икесе дә тулы зат кушымчалары алып төрләнә: يازوبمن – язымбмән,يازوبسن – язымбсән,يازوبدر – язымбдыр, يازوبمز – язымбмыз, يازوبسز – язымбсыз, يازوبلار – язымблар [Өметбаев, 1901, б. 25].

Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1927) хезмәтендә *-ган* кушымчалы фигыльләр үткән заман исем фигыль дип аңлатыла: «...үткән исем фигыльләр нигез фигыльләрнең азагына беренче рәт *-ган/-гән, -кан/-кән* төрлекләре кушылып әйтелә...» [Алпаров, 1945, б. 96].

*-ган* кушымчалы фигыльнең нинди позициядә хикәя, кайчан сыйфат фигыль була алуы, асылда, В. Хангильдинның «Татар теле грамматикасы» хезмәтендә җентекләп аңлатыла [Хангильдин, 1954, б. 246]. Хәзерге татар теле грамматикаларында әлеге мәсьәләләр ачыкланган, парадигматик һәм синтагматик мәгънәләр төгәл аерылган [Татар грамматикасы, 2002, Т. II, б. 127–128]. Татар телендә *-ган/-кан* формалы нәтиҗәле үткән заманның, башка төрки телләрдәгегә караганда, мәгънәсе ягыннан киңрәк булуы «...кайбер төрки телләрдә аның функциясе өлешчә *-ып* кушымчалы үткән субъектив заманга күчкән, бу форма татар диалектларында очрый», – дип аңлатыла. Тикшерүләр күрсәткәнчә, әлеге форманың язма текстларда кулланылуы да мәгълүм.

XIX гасырның беренче яртысында иҗат ителгән тезмә әсәрләрдә, хикәяләүне алып бара торган *-ды* кушымчалы билгеле үткән заманга караганда, нәтиҗәле үткән заманның сирәгрәк кулланылуы күзәтелә. Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» (1845, 1889) әсәрендә: Байғ идеб базара иблек ошбу хин / Алмышым белгел һиммам-әл-мөэминин [Каргалый, 1889, б. 2], Хақ өчен вирмәйә қоруғ нанынь / Кәндүя дақан мөһибләр намыны,... диб бойырмышдыр рәсүле мөхтәрәм [Каргалый, 1889, б. 3], Безләр өчен хәзрәти Ғыйззе wә җәл / Индеребдер айәте, бел һәм әзәл / Боерыбдыр Хақ Тәғалә: wәқразу / Без аны зан әйләйебмез: вәмсәкү [Каргалый, 1889, б. 4], / Ул мөбарәк Хаққә басмышдым қадәм, ...җай вирмеш иде безләрә әғлә сарай, ...йимешем ул падишаһның ниғмәтен,... һич күр-

мәмешем бер сәрвәри, ...Мисыр мөлкен забыт қыйлмыш [Каргалый, 1889, б. 12] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, нәтиҗәле үткән заманны белдерү өчен *-ып* һәм *-мыш* формалары, сирәгрәк *-н* формасының кулланылуы күренә.

Г. Кандалый шигырьләрендә эзлекле рәвештә *-ган* формалы нәтиҗәле үткән заман фигыльләрен куллана, аерым шигырьләрдә алар тезелеп бара: Үзең түргә утырғансың / Аwызыңны тутырғансың / Төгәл кәйефне қорғансың / Абыстай утырып унға. / Синең өчен таwық чалған, / Суған, балтырғанын салған, / Сән әйткәч, чақырып алған, / Йегермесен сатып унға... [Кандалый, 1988, б. 97]; ...Фатыйма, сән, сеңелем, / Бүген әллә нишләгән, / Тышы күгән қамырыңның / Эче генә пешмәгән [Кандалый, 1988, б. 105] һ.б.

*-ган/-гән* кушымчалы сыйфат фигыльләр дә эзлекле булып кулланыла: Гөлестан чәчәк атқанда / Тулы ай йирә батқанда, / Ки уйлап аны йатқанда, / Килеп баса Гөлестаным... [Кандалый, 1988, б. 116]; Китабларда бу сүзне күргәнем бар [Кандалый, 1988, б. 190]. Исемләшү очраклары күзәтелә: Йалыкғанда йазайым бер-ике юл / йанып барған йөрәккә йал була ул [Кандалый, 1988, б. 242] һ.б. Аерым очракларда *-ан* формасында файдаланыла: күрәнләр хур дийеп сана [Кандалый, 1988, б. 181]; ...күрәнләр сәне хур сайдай [Кандалый, 1988, б. 186]. Исем фигыль вазифасында кулланылуы да күренә: Әйа ғариф, бән имам булғанымдин / Сәңа йаздым үзем хур булғанымдин [Кандалый, 1988, б. 216]; ...Әйа ғариф, дөшемдә күргәнемдин... [Кандалый, 1988, б. 218], ...Мони йаздым сәни бик сәүгәнемдин / Йөрәгем утыйга бик күйгәнемдин [Кандалый, 1988, б. 228].

Аерым очракларда бу автор *-ып* формалы фигыльне куллана. I заттан хәзерге заманда бара торган сурәтләү сирәк кенә нәтиҗәле үткән заман белән чиратлаша. Әлеге форманың I зат кушымчасы белән кулланылуы аның дәвамлы булган субъективлыгын арттыра: Синең дидареңә мохтаҗ булыпмын / Тәқый ғыйшық утыйға янып-көепмен, ...Җәмалеңне күреп хәйран булыпмен / Сәне күрмәк өчен ғирьян улыпмен... [Кандалый, 1988, б. 156], ...Зифа буең күреп туймас булыбмен [Кандалый, 1988, б. 194], ...Сәнең өчен қыйлыбмын налә бисйар (күп еладым) [Кандалый, 1988, б. 203].

III зат кушымчасы алганда, үткәндә булган, нәтиҗәсе күзалдындагы парадигматик мәгънәсе белән файдаланыла: Йаратыбдыр сәне ул Хақ / Ки ақ йақут кеби һәм ақ / Йөзенә салды күп рәүнәқ [Кандалый, 1988, б. 181]. Күптән үткән хәлләрне белдерергә дә мөмкин: Зөләйха

Йосыфа ғашыйҡ улыбдыр, / Ҡулындин ҡамчысын әлә соныбдыр... [Кандалый, 1988, б. 198].

*-мыш* формалы нәтиҗәле үткән заман фигыле сирәк куллныла: Үзе – шивә, күзе – нәргис, йөзедер сахиб җәмал, / Исменә җисмен муафиҡ ҡыйлмыш аны Зөлҗәләл [Кандалый, 1988, б. 211]. Аерым очракларда тезелеп бирелә: Ҡашың ҡара сызылмышдыр, / Тешең йенҗе тезелмешдер, / Йөрәк-баwрым өзелмешдер [Кандалый, 1988, б. 214] һ.б. Шулай итеп, Г. Кандалыйның шигырьләрендә, тасвирлау чарасы буларак, төрле дәрәҗәдәге нәтиҗәле үткән заманның *-ган/-кан, -ып, -мыш* кушымчалы формалары файдаланыла.

XIX йөзнең икенче яртысынды язылган Ә. Уразаев-Кормашиның һәр ике кыйссасында да, асылда, аларның тезмә өлешендә, I һәм II затта, тулы зат кушымчасы алып, үткән заманны белдерү өчен, *-ып* формасы актив кулланыла. «Кыйссаи Бүз йегет»тә: Нә булса да булғаймән, мән бер миһман килебмән, / Нурыңны төшемдә күребмән, хәйран булыб йөребмән, / Сәне күрер көн булса, нә булса да булыбмән, / Таудин, ташдин үтебмән, бу шәһәргә җитебмән, / Йөзең күрер көн булса, ата-анадин китебмән... [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 13] һ.б. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә»дә: Тәкдир җитеб сөебмән, күп бәетләр сөйләбмән / Хур ҡызындай гүзәлне суҡҡаныңа көйебмән... / ...Күп гөнаһны ҡыйлыбмән, инде алдыңа килебмән, / Җаным сөйгән Зөһрәҗан, кич, дип өмид ҡыйлыбмән... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 8] һ.б.

Әлеге өзек-мисаллардан аңлашылганча, *-ыпмән* формасы сөйләүче үзе катнашкан, сөйләү моментына кадәр булган эш-хәлләрнең нәтиҗәсен сөйләү моментында дәвам итә, актуаль булган нәтиҗәне аңлата. Сөйләүченең үзе катнашуы, ягъни эш-хәлнең күрелеп үтү төсмере белән әлеге форма *-ды* кушымчалы фигыльнең мәгънәсенә дә якыная.

*-ып* кушымчалы үткән заман фигыль II затта сөйләүче үзе катнашмаган, сөйләү моментына кадәр булган эш-хәлләрнең нәтиҗәсен аңлата, *-ган* кушымчалы фигыльнең синтагматик мәгънәсенә туры килә. «Кыйссаи Бүз йегет»тә: Йанған утҡа төшебсән, сүндермәкең ҡыйынды... [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 23] һ.б. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә»дә: Былбыл идең йирендә, булмас йиргә төшебсән, / Ҡош ҡотҡармас ҡарчыға, бойырыҡ турыға төшебсән, / Теләб аны булмасды, бик хурлыҡға төшебсән, / Маңлаендан тир ағып, тирән йиргә төшебсән, /.../ Бирик дигән wәғдәңне онытыбсән, Зөһрәҗан, / Камил биргән күңелеңне суытыбсән, Зөһрәҗан [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 23] һ.б.

II зат тартымлы *-ыпсән* формасы берничә мәртәбә кабатлана да, *-ган* кушымчасы белән йомгак ясала: Қаты уйқуға китебсән, уйан Зөһрә солтаным, / Татлы уйқуға китебсән, уйан, Зөһрә солтаным, / Җан түшәккә йатыбсән, җан йоқыға йатыбсән, / Гашыйк йарың килгәндә, һәнүз ғафил йатыбсән, / Зиндан чикгән йиде йыл, михнәт чикгән йиде йыл, / Таһир йарың килгәндә, уйан, Зөһрә солтаным... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 57].

«Кыйссаи Бүз йегет» әсәрендә *-ып (-уб)* формалы үткән заман хикәя фигыль, II зат берлек һәм күплектәге тулы зат кушымчалары белән, үтенү, ялвару төсмерен алып килә торган боеру наклонениесе вазифасында кулланыла, һәрхәлдә, соңгы җөмләләрдә боерык фигыльнең формасы үзе кабатлана: Берең мөрәүвәт, берең мәрҗан, тезелебсез, йар-йар, / Берең хандыр, берең ханча, хуш булубсез, йар-йар, / Берең былбыл, берең тутый, йар булубсез, йар-йар, / Берең алтын, берең көмеш, қуш булубсез, йар-йар, / Берең тутый, берең былбыл, бер йөреңез, йар-йар [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 14] һ.б. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә»дә бу мәгънә Аллаһыга ялвару шәкеленә салына: Таһирҗанның хәсрәтен бар қыйлыбсән, ходайә, / Ачық йөзен күрмәгә зар қыйлыбсән, ходайә, / Мәхәббәтем йарасын бирсәң икән, ходайа... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 6] һ.б. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә»нең тезмә өлешендә *-ып* кушымчалы фигыльнең I һәм II затлары белән рәттән, аның III заты да шактый еш кабатлана: Сорнай тотып уйнаwың ғақылларым алыбдыр, / Күзләрең тегеп қараwың сүнмәс утлар салыбдыр... / ...Тәқсыйр, қызың азыбды, туғры җулдан җазыбды, / Туғры дигән Таһирның йаман уйлар салыбды... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 16] / ...Атаң қулға алыбды, фирқать утын салыбды... / Тәмам илне аралап, бик зур дошман табыбды... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 27] һ.б. *-ыпды* һәм *-ыпдыр* формалары *-ганды* һәм *-гандыр* күрсәткечләре белән чиратлашуы күзәтелә: Ғашыйқ йарың килебде, ғариб йарың килебде, / Гөл йөзеңне күрмәгә ғашыйқ йарың килебде... / Ғашыйқ йарың килгәни, тор, җанашым, торсана... / Моңлы Таһир килгәнди, уйан, Зөһрә солтаным... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 35] һ.б. Өздереп әйтергә кирәк булганда, *-гандыр* формасы кулланыла: Шатлық көнем үткәндер, қайгу көне җиткәндер / мин йыгамый нитәйен, айырылу көне җиткәндер... [Гайнуллин, 1957, б. 316] һ.б.

Аңлашылганча, Ә. Уразаев-Кормашиның һәр ике кыйссасынның текстында *-ган, -мыш, -ып* күрсәткечле хикәя фигыльләр III затта да кулланыла, бу очракта да эш бүленеше күзәтелә: кыйссаларның чәчмә

өлешендә *-мыш,* ә тезмә өлешләрендә *-ган* һәм *-ып* формалары эзлеклерәк бара. «Кыйссаи Бүз йегет» әсәрендә: Қайчан унбиш йәшенә ирешде ирсә, бер көн йатыб төш күрде, төшендә өйенә бер йегет кәлмеш, күрде: бер кеше никях қылмыш, нурлы йөзләренә хәйран қалмышлар, қыз шул сәғать уйаныб китде ирсә, ул килмеш сурәт йанында булмады [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 2]. *-ган* күрсәткечле нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльнең I һәм II заты ешрак кабатлана: Күкдә торған йолдызмән, суда йөргән қондызмән, / Хақдин билге алғанмән, нурдан өлге алғанмән... [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 4]... / Хаққа буйн сонғанмән, зар сәрғардән булғанмән... [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 8] һ.б. *-ган* формасы *-ып* белән чиратлаша: Өммәт өчен зар йығлаб, рәсүл үткән дөньйадин, / Утыз өч мең әсхаблар, алар да үткән дөньйадин... [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 54]... / Көнчыгыштан килебде, йурға атдай йилебде, / Ата-анадан айырылыб, без эзләгән булмасын [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 11].

Әлеге фигыль формаларында шундый ук эш бүленеше, нигездә, «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә да дәвам итеүә: Күрде кем, бу нийәт ийәләренең берсе падишаһ wә берсе wәзир имеш, һәр икесе бала өчен нийәт қыйлмышлар, қалдырмышлардыр... Әлеге кыйссада аның чәчмә өлешеннән тезмә өлешенә күчү *-ган* кушымчалы фигыльнең III заттагы тартым күрсәткече алган формасы белән башкарыла: Зөһрә айғаны, Таһирға бер бәqет айғаны, җан сүзе илә Таһир Зөһрәгә әйткәне, зарилык қылып әйткәне, бер назыйм айганы, һ.б. әлеге форма *-ды* кушымчалы фигыль белән чиратлаштырыла: бер назыйм әйтде, бер шигырь әйтде, җаwап бирде, бер-бер ғарыз қыйлғаны... һ.б.

«Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәренең тезмә өлешендә III заттагы *-ган* кушымчалы үткән заман хикәя фигыль үзенең төп-парадигматик мәгънәсе белән, ягъни үткәндә булган, әмма нәтиҗәсе сөйләү моментында актуаль булган эш-хәлләрне белдереп кулланыла: Йәшем басқан күземне, хәсрәт алған үземне... / Шадлық көнем үткәндер, аһ-зар көне йиткәндер... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 22]... / Шадлық көнем үткәндер, қайғум көне йиткәндер, / Мин йығламый нитәйен, айырылу көне йиткәндер... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 42].

*-ган* формасы белән күптән үткән заман мәгънәсе дә белдерелә: Зөһрә йардан айырылыб күб заманлар үткәндер... / Атаң падишаһ булғандыр, бақ, дәүләте тулғандыр... / Сезне безгә бирмәгә шаһым вәгдә қыйлғандыр... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 42]. Түбәндәге юлларда, контексттан аңлашылганча, *-ган* күрсәткечле фигыль киләчәк за-

манның мәгънәсендә кулланылса кирәк. Зөһрәнең, Таһир күргән яман төшне юрап, «Ғыйшық йиле, белмәймән, қай йирләргә атади» дигән шөбһәләнүенә каршы Таһирның сүзенә җавап итеп, әйтә: Күңелем ғорьян улғандыр, җекерем бер йан улғандыр, / Йалған дөньйа, Таһирым, сәнсез хәрам улғандыр... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 20], ягъни «Күңелем ялангач булыр, күзләрем кайгы уты белән тулы булыр, / Ялган дөнья, Таһирым, синсез тыелган булыр (булачак)» дип аңлашыла.

Акмулланың «Дамелла Шиһабеддин хәзрәт мәрсиясе» шигырендә *-ган* күрсәткечле III заттагы нәтиҗәле үткән заман фигыле, парадигматик, ягъни үткән, әмма нәтиҗәсе хәзерге заман өчен актуаль булган эш-хәлләрне белдерә торган мәгънәсе белән әсәрнең эчтәлеген дщвам итүдә сәнгатьчә форма рәвешен ала: ...Қараңғыда фанусны кабызған ул, / Қайнар сөткә сары майны тамызған ул... / ...Әнһарул-хакаиқны ағызған ул... / Ходаем фәрасәтле йөрәк биргән... [Акмулла, 1892, б. 2]; ...Дәкаиқдә мөшкел чишеб қалдырған ул / Биш йөз йылғы батырларны талдырған ул / Мисаленә әһле ғасыр ғадил тапмай / Йөрәген мөғаниднең йандырған ул [Акмулла, 1892, б. 3] һ.б.

*-ган* кушымчалы фигыль күптән үткән заманны белдереп, синтагматик мәгънәсендә кулланыла: Дошманға пәйғамбәр дә ярамаған / Сары май эт қарнына өнәмәгән /...Қылғаны бер Ходайға ярамаған / Пәйғамбәр сөйләгәнен қаламаган (кабул итмәгән) [Акмулла, 2001, б. 71] һ.б.

I заттан сөйләгәндә, *-ган* кушымчалы форма киңәйтелгән-дәвамлы хәзерге заманны белдерә: Мин бер арық бүредәй җилеп йөргән / Қуйан, қарсақ, төлке исен сизеп йөргән / Берәwе қулға төшсә, бере төшмәй / Арық, ақсақ, кәиз килсә, элеп йөргән [Акмулла, 1892, б. 3],

*-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләр дә актив кулланыла: Уйламаңыз «Җарудә»не күргән юк дип, / Әгәр күрсә, ғыйбарәтен белгән юк дип, / Қадәри халь садақ тартқан йегетләр бар / Уйламаңыз дөньйада мәргән җук дип... [Акмулла, 1892, б. 4]; Ул бер ғалим икән сөйләй торған / Ғоләмә мәҗлеседә мәйдан алған / Морадына мөнафины сөймәй торған / Қурайы килешкәндә көйләй торған... [Акмулла, 1892, б. 10] һ.б.

*-ган* кушымчалы фигыль исем фигыль функциясендә файдаланыла: Унбиш ел «Назурә»сен алғаныма / Қарай-қарай баш очыма салғаныма... [Акмулла, 2001, б. 9].

*-ган* кушымчалы фигыль инфинитив вазифасында: Мәғнәләп инде әйтәйем, қарамаган (карамакка мәгънәсендә) [Акмулла, 2001,

б. 71] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, М. Акмулла иҗатында *-ган* кушымчалы үткән заман хикәя фигыль үзенең барлык мәгънәләре белән дә тасвир-сурәтләү чарасы булып файдаланыла. *-мыш* формалы фигыль күзәтелми, *-ып* кушымчасы белән күрсәтелә торган үткән заман бер мәртәбә очрады: ...Мөхкәмә қылмас дип уйладыңмы / Суқыр дип белепмедең йортның барын... [Акмулла, 1892, б. 6; 2001, б. 17].

Г. Тукай һәм Дәрдемәнд иҗатында нәтиҗәле үткән заманның ничек итеп кулланылуын махсус тикшерергә кирәк булачак. Бу урында *-ган* кушымчалы фигыльнең а) парадигматик һәм ә) синтагматик мәгънәләре белән нинди гүзәл тасвир барлыкка китерү өчен файдаланылуларына бер-ике мисал китерәбез. Г. Тукайның «Туган авылым» шигырендә: Тау башында салынғандыр безнең аwыл... / Ходай шунда җан биргән, мин шунда туған, / Шунда әүwәл Қоръән айәтен уқыған, / Шунда белдем рәсүлебез Мөхәммәдне / Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торған...

Дәрдемәнднең «Рәсем» шигырендә: Тәнкәен ақ, түшкәйләрен киң йаратқан, / Биткәйенең иң очында миң яратқан, / Сақлар өчен зифа буйын йаман күздән, / Чәчкәйләрен айақ белән тиң яратқан... һ.б.

Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, *-ган* кушымчалы фигыльләр үзләренең парадигматик мәгънәсе белән кулланыла, сөйләү моментына кадәр булган, нәтиҗәсе күз алдында, әмма күрелеп үтмәгән эш-хәлләрне аңлата, бу мәгънә лексик чаралар белән дә ныгытыла...

Шуның белән бергә, *-ган* кушымчалы үткән заман хикәя фигыль үзенең синтагматик-күптән үткән мәгънәсе белән дә сурәт ясау чарасына әверелдерелә: ...Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән, / Анлары төнләр буйы әбкәм хикәйәт сөйләгән... («Туган тел»); ...Электә бер ташчы торған бу дөньйада, / Безнең йирдә түгел, йырак Йапунийәдә, / Үзе булған таза ғына бер яшь кеше, / Ялықмыйча эшли икән ул таш эше.. («Япун хикәясе»); ...Киткән урманға утынға, ялғызы бер ат җигеп, Тиз барып җиткән йегет, эшкә тотынған барғач уқ, / Кисә башлаған утынны балта берлә туқ та туқ... («Шүрәле») һ.б.

Шулай итеп, XIX гасырның беренче һәм икенче яртысында, шулай ук XX йөз башында иҗат ителгән тезмә әсәрләрдә *-ган, -ып, -мыш* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльнең һәр формасы һәм мәгънәләре һәр авторның максатына туры китерелеп сайланып кулланыла.

Шушы ук тәртип XIX гасыр ахыры – XX йөз башында иҗат ителгән чәчмә әсәрләрдә дә күзәтелә.

К. Насыйриның тәрҗемә итеп басылган кыйссаларында *-ган* кушымчалы фигыль рәттән, эзлекле рәвештә сыйфат фигыль вазифасында, аннан кала исем фигыль һәм «соң» бәйлеге белән хәл фигыль мәгънәләрендә, инде шуннан соң гына (ягъни сан ягыннан азрак булып) үткән заман хикәя фигыль мәгънәсендә кулланыла, гадәттә III зат берлек һәм күплектә бирелә. Хикәяләүне алып баручының фикере буларак әйтелгән очракта, *-ды* кушымчалы үткән заманның мәгънәсе кебек үк, шактый шартлы була, бер үк контекстта шул ук *-ды* формалы фигыль белән алмаштырылып кулланыла ала. «Кырык вәзир кыйссасы»нда: ...Олуғ уғлан әйтде: кийәү мөрәүвәтле икән, ...кызға рөхсәт бирде... Уртанчы уғлан әйтде: сөйгән йегете мөрәүвәтле икән, ...зифа қыз қуеныңа кергән, ...кире кияү янына күндерде. Кече уғлан әйтде: хақ мөрәүвәт иясе уғры икән, ...бу қадәр назәнин қыз аның тозағына кергән, ...қызны барасы йиренә илтеп қуйды [Насыйри, 1975, б. 143]. Әлеге җөмләләрдән аңлашылганча, *-ган* күрсәткечле фигыльдә (кергән) билгеле бер нәтиҗәлелек төсмере салына, әмма бу фигыль белән белдерелә торган эшнең кем тарафыннан күрелеп үтү-үтмәү факты яисә сөйләү моментына ни дәрәҗәдә бәйле булу-булмавы анык итеп бирелә алмый, чөнки текстта, хикәяләү процессында, әлеге мәсьәләләр үзләре шартлы, ягъни автор да, персонаж да тәгаенләнмәгән. Кеше сүзен сөйләп хикәяләнә торган К. Насыйри прозасында *-ды* кушымчалы фигыль, җөмләнең мәгънәсен үзгәртмичә, аның урынында кулланыла ала торган башка заманнарга уртак-инвариант форма булганы кебек, әлеге хикәяләрдә *-ган* кушымчалы фигыль, нигездә, шул вазифаны үти дип әйтергә мөмкин.

Ә инде *-ган* кушымчалы фигыль гомуми зат фикере буларак бирелгәндә, халык авыз иҗатының мәкаль-әйтемнәрендәге кебек, сөйләү моментына кадәр күптән әйтелгән, әмма нәтиҗәсе һәрвакыт мәгълүм, бар кешегә дә билгеле булган эш-хәлләрне аңлата; ...әйткәнләр ки, бераз ғына һөнәр булса да, йөз мең алтындан хәйерледер [Насыйри, 1975, б. 165] һ.б. Бу төр фигыльләр *-дыр* аффиксы белән бирелгәндә, нәтиҗәнең катгыйлыгы арта: Әйткәнләрдер ки, ғайре кешегә қойы қазысаң, тирән қазы, ихтимал үзең төшәрсең [Насыйри, 1975, б. 167].

К. Насыйри әсәрләрендә *-ган* күрсәткечле фигыльнең I һәм II затларда тулы зат кушымчалары белән кулланылуы, III зат белән чагыштырганда, шактый сирәк, һәр тексттан берничә мисал-өзек кенә китерергә мөмкин. «Кырык вәзир»дә: Хуҗаларның берсе әйтде: син бүген тәмле ашағансән, диде. «Әбүгалисина»да: ...син

хата килгәнсән, диде. «Бар» һәм «юк» сүзләре янәшәсендә, тартым кушымчалары белән кулланылу очраклары ешрак күзәтелә: ашағаным йуқ, күргәнем йуқ һ.б.

К. Насыйри әсәрләрендә *-ган* кушымчалы фигыль үзенең сыйфат фигыль һәм индикатив мәгънәләрендә *-мыш* формалы фигыль белән шактый чикләнгән санда алмаштырылып кулланыла, вакыйганы алып баруга берниндидә тәэсир итмәслек дәрәҗәдә *-ган иде, -мыш иде* формалары һәм, Казан тарихына караган берничә мәкаләсендә, *-ып, -ыпдыр* кушымчалы фигыльләрнең файдаланылуы күзәтелә: ...Нуғай йулы wә һәм закама халқын димләп, чуқындыру хезмәтен қушыбдыр, ...шуннан үзләре Истамбулға қачыбдыр, ...илче килебдер, ...камчат бүрек бirебдер, ...аңа барығыз дийебдер, ...әмер итебдер һ.б. [Насыйри, 1974, б. 73 һ.б.].

Татар прозасының угызлашкан вариантында язылган М. Акъегет һәм З. Бигиевнең әсәрләрендә *-ган* кушымчалы фигыльләрнең һәм сыйфат фигыль, һәм индикатив мәгънәләре эзлекле рәвештә *-мыш* формасы белән файдаланыла, шулай итеп, әлеге күрсәткечләр үзләренең функциональ-стилистик вариантлылыкка ия була алуларын күрсәтә. Әлеге әдипләр, мәгълүм булганча, К. Насыйри кебек, татар халкы укысын дип кенә түгел, бәлки тулаем төрки дөнья укысын дигән максатны күздә тотып яза, шуңа күрә дә традицион язма-угыз формаларын да иркен кулланалар. Сыйфат фигыль мәгънәсендә файдаланганда *-ган* күрсәткече урынында *-ан* формасы эзлеклелек ала.

«Хисаметдин менла» романында *-ган* кушымчасының нәтиҗәле үткән заман мәгънәсендә кулланылуы түбәндәге өзекләрдә бирелә: Хәнифә туташ көлә-көлә кийәр: – Бақ, нинди чақ килде, әйтерсен бармағыма үлчәнгән [Насыйри, 1886, б. 28]. Бәнем Хисаметдинем алырға пәк өстәде, әмма нә қыйлырсән. Күрәсән йазылмаған. Бән аңа әйтәмән: уғылым сабыр ит, йазылмаған; ул әйтәдер: Йәшьмә, анай. Нинди йазылмаған, йазылған [Насыйри, 1886, б. 51–52]. Күренгәнчә, ике өзек тә персонажларның үзара сөйләшүе итеп бирелә, автор, димәк, аларның сөйләмен табигый хәлендә тасвирларга тиеш дип тапкан.

З. Бигиев әсәрләрендә дә, нигездә, шундый ук хәл, ягъни *-ган* күрсәткечле индикатив персонажлар сөйләмендә файдаланыла: Бән сезгә мәктүб язған идем, шайәть алғансыз. ...шайәть wәғдәңезне онытмағансыз? – диде. Җәмәғать телендән бу кеби сүзләр дә ишетеленер иде: Иртә кәлдек, чәй эчеп кәлгән булсақ та, кичекмәгән булыр идек. ...Зөләйханың җан тәслим кылдыгыны күреп, револьверны алгандыр

һәм дә Зөләйха, үз-үземне кател итәмән дәйү язып қалдырған кәғазен дә револьвер илә нумирдан уғырлап алып чыққандыр..., – дәйү господин Шубин сүзен тәмам иткәч, ...Әхмәди байға мәктүб җибәргәнеңез барму? Муса әфәнденең сәламәтләнүе хақында мәктүб язған идек, анлардан бер дә хат-хәбәр алғанымыз йуқ... [Бигиев, 1887, б. 78].

*-ган* күрсәткечле нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльне аерым бер стиль-жанрның таләбенә туры китереп, аңа яраштырып куллануга мөмкин булу, беренче драма әсәрләре һәм балалар өчен төзелгән уку әсбапларының текстларында да ачык күренә.

Персонажларның кара-каршы сөйләшүе булып бара торган драма әсәрләрендә халык сөйләменә хас булган формалар, шул исәптән, *-ган* кушымчалы үткән заман фигыль дә актив файдаланыла: Фатыйма – Сезне бит Тимербайның уғлы Җантимергә бирәләр имеш дип, халық өстенә таралған. Фәрихә – Йуқ, қызым, авырый торғансыңдыр. ...асраулары белән сөйләшкән, ...бу чақта йегетләр сайланған, ...мин қызғанам [Ильяси, 1887, б. 9]. Менә шул рәвешчә, драма әсәрләрендә *-ган* кушымчалы фигыль үзенең барлык мәгънәләре белән кулланыла, драма әсәрендә бара торган вакыйга-хәлләрне алып баруда төп көч, төп чара булып тора. Әлеге үзенчәлек Г. Камал һәм Г. Исхакыйның беренче драма әсәрләрендә дә дәвам ителәә.

Димәк, җанлы сөйләм халәтен бирү өчен, драма әсәрләрендә, хәзерге һәм билгеле үткән заман фигыльләре белән берлектә, нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль дә үзенең барлык мәгънәләре белән кулланылыш таба. Т. Яхинның җыентыгындагы әсәрләрнең теле, асылда, халыкның җанлы сөйләменә якынайтып бирелә. «Карга илә төлке»дә: Бер заман карга тапкан бер кисәк казылык. Моның соңында карга ул казылыкны агызына кабып, агач башына кунып, тәмам ашар вакытда, карга кунган агач төбенә акрын гына килгән. Төлке ничек кенә булса да хәйлә табып, казылыкны ашамакчы улып хәйлә төзегән. Койрыгыны уңга-сулга бәреп, майлы күзен каргадан алмый, карганы мактарга керешкән. ...Шул сүзләрне карга ишетеп агызын зур итеп как дип кычкырган да казылык кисәгене төшереп йибәргән... [Яхин, 1902, б. 2–3]. Барлык хикәяләр дә, нигездә, шушы тәртипне саклап төзелә: бер үк диярлек сүз һәм сүзформалар кабатлана, «бер заман» дип башлау халык әкиятләренә якынайта, *-ган* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман фигыльнең җөмлә саен кабатланып, фикерне тәмамлап куюы, билгеле бер ритм хасил итә, нигездә, сөйләү моментына кадәр күптән үткән, сөйләүче үзе катнашмаган-күрмәгән, әмма

күп кешеләргә мәгълүм эш-хәлләрне укучыга җиткерү мәгънәсе белән кулланыла.

*-ган* күрсәткечле нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльнең функциональ-стилистик вариантлылык барлыкка китерүдә, башка заман формаларына караганда, ныграк әзерлеге, төрле жанр-стильдә иҗат итүче мәгърифәтчеләребез иҗатында да нык сиземләнә. Бу очракта Ф. Кәрими һәм Р. Фәхретдин әсәрләре күз алдында тотыла.

Ф. Кәрими, мәгълүм булганча, үз чорындагы татар әдәби теленең өч варианты белән дә иҗат итә: сәнгатьле прозасы, асылда, иске татар әдәби теленең гавамлашкан төре белән, сәяхәтнамәләре иске татар әдәби теленең җәдиди госманлы дип атала торган варианты белән, ә инде мәктәп-мәдрәсә, фән һәм дингә багышланган хезмәтләре иске татар әдәби теленең гарәп-фарсы алынмалары күбрәк кулланыла торган варианты белән иҗат ителә, ягъни сүз һәм сүзформалар махсус сайлана, бу хәл заман парадигмаларыннан файдалануда да чагылыш таба.

Үзеннән-үзе аңлашылганча, *-ган* кушымчалы фигыльләрнең сыйфат фигыль мәгънәсен белдерүе дә, хикәя фигыль булып кулланылуы да Ф. Кәриминең сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә тасвир чарасы булып файдаланыла: ...Бу рисалә беренче мәртәбә басылып чыкканда, халкымыз йаратмады. Бик каты язган. Комганнан көлгән. Чапаннан көлгән. Голәмага тел тидергән. Шәригатьне тәхфиф иткән, – диделәр [Кәрими, 1996, б. 30]. ...Якынрак барып карасам, ...бер ашъйаулык җәйгәнләр, ...кулъйаулыкка бераз турап куйганлар. Тирә-йакларына руслар җыйылган... [Кәрими, 1996, б. 33].

Ф. Кәриминең төрле әсәрендә, аның темасына, вакыйганың кайда баруына мөнәсәбәтле рәвештә, *-ган* кушымчалы фигыль *-мыш* формасы белән дә чиратлашып кулланыла: Голуме динийә тәхсиленә махсус мәдрәсәи исламийәсе һәр җирдә мәшһүр wә мөдәррис мәрхүм Мөхәммәдзакир хәзрәтнең гайрәт wә һиммәте фазыйланәләре сайәсендә, бу мәдрәсәдә бер чук таләбе җитешмешдер [Кәрими, 1996, б. 56]. Әлеге җөмләдә *-мыш* формасы, гарәп алынмалары белән берлектә, әйтелә торган фикернең бөеклеген, авторның Мөхәммәдзакир хәзрәткә карата соклануын белдерү өчен файдаланыла. Түбәндәге җөмләдә шул ук кушымча бер үк форманы кабатламау өчен кулланыла: Тауның һәр тарафы агачлык илә капланмыш. Шул агачлыкларның арасында Пенза губернасыннан килгән бер мишәр кымыз заведениесе корган [Кәрими, 1996, б. 63]. Түбәндәге җөмләләрдә исә *-мыш* формасы Кырымның үз төбәк теле булганга үзгәртелмичә генә алына: Кырым – Ру-

сийәнең җәнүб тарафында, Қара диңгезгә туғры озайып чықмыш бер атау булып, қорыға Перекоп исемле тар бер бәрзах илә тоташмышдыр [Кәрими, 1996, б. 108] һ.б.

Ф. Кәрими үзенең сәяхәтнамәләрен барлык төрки дөнья укысын дигән максаттан чыгып, «Тәрҗеман» газетасының «уртак лисан»ына якын булган тел белән яза, шуңа күрә дә традицион язма, ягъни угыз формалары эзлеклерәк сайлана. «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902) болай башлана: ...Иске заманларда бу хәзерлекләр китәчәге йулның wә гизәчәге wакытның озынлығына нәзарән иҗра иделмешдер, яғни ... wә озын сәфәрләр өчен бик чуқ хәзерлекләр күрмәк лазем килмеш. ...һәр алмашындығы кеби сәйәхәт мәсьәләсе дәхи бик чуқ тәбдил идмешдер [Кәрими, 1902, б. 2; 1996, б. 150].

Р. Фәхретдин иҗатында тел мәсьәләсе тагын да катлаулырак. Аның сәнгатьле прозасында, аерым алганда «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә (1899) бара торган вакыйгалар, башлыча, менә бу типтагы җөмләләр белән бирелә: Қазан – ...Қазан йылгасының сул йағында wә Итилгә қушылган урында бийек түбәгә бина иделмешдер. ...Қазан шәһәрендә улған мәдрәсәләренең берендә ун йыл қадәр уқымыш идем. ...асыл ватанымны wә җаным бәрабәрендә улған анамны қалдырып, ничә йөз чақрым мөсафәдә Қазан шәһәренә йулланмыш идем [Фәхретдин, 1899, б. 3–4]. Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, *-ган* кушымчалы фигыль рәттән диярлек сыйфат фигыль ролендә, ә *-мыш (дыр)* формасы нәтиҗәле үткән заман мәгънәсендә, *-мыш иде* әлеге нәтиҗәне сөйләүченең искә төшерүе мәгънәсендә кулланыла.

Әдипнең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) әсәре дә, нигездә, шушы төрдәге җөмләләр белән бирелә, әмма монда сыйфат фигыль булып килә торган *-ган* формасы, еш кына, *-ан* булып языла: Сәлим бабай бу йаман ғадәтне Ғаббас мелладан үгрәнмеш дәгел, бәлки Ғаббас меллаға кәндесе үгрәтмеш иде [Фәхретдин, 1903, б. 4–5].

Һәр ике әсәрдә дә персонажлар сөйләмендә *-ган* кушымчалы фигыль нәтиҗәле үткән заман мәгънәсендә: Нә өчен бундай озын ад қуйғанлар, ...бу шәһәргә килгәч, хуҗа хатындан ойық бәйләргә үгрәндем. – Уқырға, йазырға үгрәндеңме? Бән үзем дә намаз уқырга үгрәндем [Фәхретдин, 1899, б. 41]. Бу китап Қазанда ташқа басылган. – Дөресме, ташқа басылғанмы? Бона үзең дә күрәсең, басылған. ...аны зәкйатдан таратырға үзләре белмәгән булырлар иде, ләкин дамеллалар анларға буйлә мәшрут биргәнләр... [Фәхретдин, 1903, б. 4–5].

Р. Фәхретдиннең «Тәрбияле ана» һәм «Тәрбияле бала» (1898) хезмәтләре «ачық ана телемездә йазылмышдыр», димәк, мөмкин дәрәҗәдә әдәби тел халыкчан варианты белән кулланыла, *-ган* кушымчалы фигыль дә халык сөйләмендәгечә бирелә, башлыча, сыйфат фигыль мәгънәсендә килә: ...Бик йарлы булған өйләр эчендә тәрбийәле ана булса, ул өй олуғ байлардан саналынадыр. Бик бай булған өйләр эчендә тәрбийәле аналар булмаған сәбәбле, бик йарлы күрелмәкдәдер [Фәхретдин, 1898, б. 3]. ...йахшы балалар үсдергән йитешдергән аналарны һәм һәркем мәдех идәдер. ...Тәрбияле аналар тугрысында пиғамбәремез Мөхәммәд (салиаллаһе ғаләйһә wәссәлам) «оҗмах аналарның айақ астларындадыр» димешдер [Фәхретдин, 1898, б. 4]. Әдипнең башка нәсыйхәт хезмәтләрендә дә индикатив, нигездә, *-мыш* формасы белән белдерелә: «Алла тәғалә хәзрәтләре үзләренең олуғлығыны белдермәк өчен ошбу галәмне йаратдырып, хисабыз мәхлүкатның арасында инсанларны ғақыл илә башкалардан айырым итмешдер. Бу мәхлукатны күбәйтмәк, үзенә мәғлум булған вакытға қадәр, тәртибенчә тотмақ, ир илә хатынларның (мөзәккәрләр илә мөәннәсләрнең) бер-беренә мәйел wә мәхәббәт идеп, катнашып, тереклек қыйлуларына бағланмышдыр» [Фәхретдин, 1899, б. 2] һ.б.

Мәгърифәтче әдипләребездән килә торган шушы үзенчәлек, ягъни нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльнең *-мыш* кушымчасы белән дә белдерелүе, классик әдипләрнең беренче әсәрләрендә дә (төрлесендә төрле дәрәҗәдә) дәвам ителә.

«...әдәби телне үз телемез димен. Үземез сөйли торған телдә йазарға тиеш, димен һәм язамын», – дип эшкә керешкән Г. Исхакый әсәрләрендә, әлеге традицион форма, милләт язмышы хакында язылa торган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1904) әсәрендә берничә мәртәбә кабатлана: Китабым бик ачы лисан берлән йазылмышдыр. Хосусән, халқымыз ғыйндендә иң мөқатдәс саналған «ғоляма» сыйныфына бик қаты туқынылмышдыр... [Исхакый, 1904, б. 4] һ.б.

Әдипнең башка әсәрләрендә *-ган* кушымчалы фигыль, үзенең барлык вазифалары белән дә, халыкчан формасында кулланылышта була. М. Гафури, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Ибраһимов кебек әдипләрнең беренче әсәрләрендә *-мыш* формасы шактый актив дияргә мөмкин, әмма ундүртенче-унбишенче елларда алар халыкчан вариантка алмаштырыла; кулланылган очракта ул персонажның сөйләмен, характерын, аңа карата автор мөнәсәбәтен белдерү чарасы булып аңлашыла.

*Кыскача нәтиҗәләр.* Тикшерелә торган чорда иҗат ителгән әсәрләрдә *-ды, -ган, -мыш, -ып* күрсәткечле синтетик үткән заман хикәя фигыльләре кулланыла. II төр зат-сан кушымчалары алып төрләнә торган *-ды* кушымчалы билгеле үткән заман вакыйга-хәлләрне алып баруда, информация бирүдә, төп чара буларак, үзенең барлык мәгънәләре белән дә файдаланыла, әмма чәчмә әсәрләрнең кем һәм ничек итеп хикәяләнүенә карап, төрлечә реальләшә: *-ды* күрсәткечле фигыль, теләсә нинди башка заман белән алыштыра алганга, хикәяләүдә «инвариант заман» буларак аңлашыла, әмма «кеше сүзен» сөйләүченең күрү ноктасын саклый. Автор үз сүзен сөйләп хикәяләнә торган мәгърифәтчеләр иҗатында *-ды* формалы фигыль сөйләмдәгечә табигый халәтендә файдаланыла. Классиклар иҗатында исә, сөйләүче «мин»нең аерым кеше сөйләме генә булмыйча, күп мәгънә белдерә торган, ягъни күрү ноктасы киңәйгән хәлдә, чынбарлыкны образлап хикәяләү башлана. Бу юнәлештә заман формаларының ничек итеп кулланылышын җентекләп өйрәнәсе бар.

Тикшерелә торган чорда *-ган, -мыш, -ып* күрсәткечле синтетик нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльләрнең, төрле жанр-стильләрдә кулланылганда, мәгънә һәм вазифалары ныграк тәгаенләнүе күренә.

Татар халкының җанлы сөйләменә якынайтып язылган сәнгатьле проза, драма, поэзия әсәрләре һәм балалар өчен тупланган текстларда, шулай ук кайбер дини-дидактик һәм фәнни хезмәтләрдә *-мыш* формасы файдаланылса да, *-ган* формасы активрак кулланыла.

М. Акъегет, З. Бигиев, Ф. Кәриминең иске татар әдәби теленең җәдиди госманлы варианты белән иҗат ителгән сәяхәтнамә һәм фәнни хезмәтләрендә, Р. Фәхретдиннең сәнгатьле прозасында *-ган* формасы да файдаланыла, әмма *-мыш* күрсәткече актив. Димәк, бу формалар төрки телләрнең язмачылыгында угыз һәм кыпчак телләренә хас булган аерымлануны күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, күрсәтелгән вакыттагы язма текстларда *-ган* күрсәткечле фигыльнең *-мыш* һәм *-ып* күрсәткечле фигыльләр белән синонимик рәт хасил итеп файдаланылуы, әмма алга таба аларның вазифасын да үзенә йөкләп, алардан аерымланып китүе нәтиҗәсендә, әдәби телдә синтетик үткән заманнарның дүрттән икегә генә калуы, язма традициянең сөйләмә нормага юл бирүе булып кабул ителә.

Мәгълүм булганча, үткән заман хикәя фигыль, синтетик төрләре белән бер үк вакытта, аларга һәм хәзерге-киләчәк заман күрсәткечләренә *иде* ярдәмлеге кушылып, аналитик төрләрендә дә кулланыла.

Хәзерге әдәби телдә алар өчәү: *-а иде, -ган иде, -а торган иде* [Татар грамматикасы, 2002, б. 128–134]; диалект-сөйләшләрдә – унбер: *-а иде, -а (дыр) иде, -а торган иде, -ыр иде, -ган иде, -ганда иде, -ды иде, -ачак иде, -улы иде, -учан иде, -учы иде* [Юсупов, 2004, с. 416–456]. XIX гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән әдәби әсәрләрдә үткән заман хикәя фигыльнең түбәндәге унөч формада кулланылышта булуы күзәтелә: *-р/-маз иде (ирде), -йур иде, -а (дыр) иде, -мыш иде, -ган иде, -макда иде, -а торган иде, -ачак иде, -мак (-лык) иде, -учан иде, -ып иде, -ды иде, -уда иде.* Аңлашылганча, өйрәнелә торган язма текстларда хәзерге әдәби телгә хас булган, җанлы сөйләшләрдә файдаланыла һәм язма традициянең дәвамы буларак кулланыла торган (*-йур иде, -мыш иде*) формаларның файдаланылуы күренә. Диалектларда мәгънәләре буенча аерылып карала торган *-а иде* һәм *-а(дыр)* формаларының [Юсупов, 2004, с. 416, 424] язма текстларда аерылмыйча кулланылуы күзәтелә.

Татар теле фән буларак татарларның үзләре тарафыннан тикшерелеп языла торган грамматикаларда фигыльләрнең ялгыз (бәсыйт) һәм кушма (мөрәккәб) булып, ягъни бир-, ал-, бел-, бул- ярдәмлекләре белән ясалган аналитик фигыльләр рәтендә *иде* белән ясала торган фигыльләргә дә игътибар ителә. Г. Фәезханов үзенең «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» (1887) хезмәтендә аларны хикәя фигыль дип атый [Фәизхан, 1887, б. 27]. Әлеге хезмәттә автор татар халкы сөйләшкәндә файдалана торган фигыльләрне билгеле бер эзлеклелектә тикшерә: кагыйдәләрен һәм мисалларын бирә, үзеннән соң тикшеренүчеләргә ныклы нигез ясый.

К. Насыйриның «Әнмүзәҗ»ендә (1895) *-р иде* формасы *җөзьәи шарт,* ягъни шартның бер өлеше, аңа бәйле булган фигыль дип аңлатыла, *-ган иде* формасын үткән заман кушма фигыль, ягъни *мөрәккәб сыйгалар мазый* дип бирә, *-са иде* формасын *сыйгаи тәмәнни,* ягъни теләү, өмет итү, ялвару фигыле дип атый, *-а иде* күрсәткечле фигыль искә алынмый [Насыйри, 1895, б. 75–77].

М. Өметбаевның «Татар нәхүсенең мохтәсары» (1901) дәреслегендә *-а иде* формасы мазый мәҗһүл, ягъни үткән билгесез, *-р иде* формасы – *мазый чәндбар,* ягъни берникадәр элек үткән, *-ган иде – мазый гөзар,* ягъни үткән үткәннең I нче дәрәҗәсе, *-ып иде – мазый гөзар,* ягъни үткән үткәннең II нче дәрәҗәсе, *-а торган иде – мазый бәгыйд чәндбар,* ягъни берникадәр электән элегрәк үткән заманнар дип бирелә [Өметбаев, 1901, б. 26–27]. Галимнәр белдергәнчә, *-р иде* үткән

заман хикәя фигыльнең шарт наклонениесе белән мөнәсәбәттә булуы аңлашыла, руник язмаларда ук кулланылышта булганга күрә, үткән заманның иң борынгы формасы дип санала [Юсупов, 2004, с. 435].

Шулай итеп, татар теле фән буларак өйрәнелеп язылган беренче хезмәтләрдә татар халкының сөйләмә телендә актив кулланыла торган формаларның барысы да диярлек анализлана, төрләнеш үрнәге китерелә, мисаллар күрсәтелә. Бу хезмәтләрдә әйтелгән фикерләр 50 нче елларның ахырларына кадәр дәвам ителә.

XIX гасырның беренче яртысында иҗат ителгән тезмә әсәрләрдә үткән заман хикәя фигыльнең югарыда саналган кайбер аналитик формаларының кулланылышта булуы күренә. Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әл-Сәгыйди»(1845, 1889) әсәрендә *-рды, -улыр ирде, -әйләр ирде* формалы фигыльләрнең I зат күплек кушымчасы алган хәлдә, авторның Коръән аяте кушканча инсафлы, иманлы булып яшәсәк кенә, ахирәт өчен дә куәтле – ризыклы булырбыз дигән теләге җиткерелә: ...Йуқ ирер Қорьанә йа иманымыз?! / Бу икедән хали ирмәз халемез? / Юхсә инсафә килердек без дәхи / Бохле тәрк идеб, улыр ирдек сәхи / Хашр-ү-нәшрә әйләр ирсәк иғтиқад / Ахирәтчен әйләр ирдек куәт-зад... [Каргалый, 1889, б. 4]. Эш яки хәлнең тәмамланмаганлыгы, дәвам ителеше аңлашыла: ...Идәрде әһле көффәрә җәзаи-Кяферләрне җәзалый иде [Каргалый, 1889, б. 5] һ.б. Шуның белән бергә, әлеге форманың тәмамлана торган эш-хәлләрне белдерү өчен дә кулланыла алуы күренә: Әгәр тәшнә улыб, аб улса хаҗәт / Wә йә улыр исә хины мәҗәғать / Чыгыб аб зәлал дәнданларындин / Китәрде тәшнәлек мәзкүр вәлидин [Каргалый, 1889, б. 5]. Бу очракта *-рды* фигыле белән, *-мыш иде* фигыле белән башланган, ягъни тәмамланган мәгънә дәвам ителә. Шул ук вакытта *-рды* формасының тәмамланмаган, киләчәктә дә дәвам ителәчәк мәгънәне белдерә алу вазифасы да кулланыла: ...Нәқадәр үсдекчә ул вәлад сәғыйрь / Күңләке һәм үсеб улырды кәбир... [Каргалый, 1889, б. 8], ягъни кечкенә бала үсә барганда, аның күлмәге дә үсә барыр һ.б. Аерым мисаллардан күренгәнчә, *-рды, -р ирде* кушымчалы үткән заман фигыле, баш җөмләнең хәбәре буларак, *-са* кушымчалы иярчен җөмлә белән вакыт мөнәсәбәтендә бирелә.

XIX гасырның икенче яртысында язылган тезмә әсәрләрдә *-р иде (-рды)* формалы фигыль бик актив кулланыла дип әйтеп булмаса кирәк.

Г. Чокрыйның «Ләбибемә» шигырендә: Ләбибем дип сөйәр иде атамыз / Әдибем дип сөйәр иде анамыз / Йәнә һәрдәм Ғалкәшем дийер

иде ул / Йәнә шонча, нәфис әлкаблар илә / Атаб, дағый булырларде, йар илә... / ...Атам разый булырде бик уқырга, / Үзем дә бик сәғи қылған булырдем, / Кичә-көндез хафизлардан булырдем... [Татар поэзиясе..., 1992, б. 333]. Аңлашылганча, *-р иде (-рды)* формалы фигыльләр тәмамланмаган, үткән заман сөйләү моментыннан алда булган, үткәннең бер моментында процесс рәвешендә башкарылган эш-хәлләрне белдерә торган мәгънәсе белән кулланыла.

М. Акмулла иҗатындагы кебек үк, Г. Кандалый шигырьләрендә дә *-р иде (ирде)* үткән заман хикәя фигыле сирәк кулланыла, тәмамланмаган, дәвамлы булган эш-хәлләр I төр зат-сан кушымчасы белән белдерелә: Сәнең өчен көнен-төнен көйәмен / Уқыр идем көндез әлемә алып / Йатыр ирдем кичен күкрәккә салып... [Кандалый, 1988, б. 228] һ.б.

Поэзия әсәрләреннән аермалы буларак, *-р иде* үткән заман хикәя фигыле татар прозасының кеше сүзен сөйләп хикәяләнә торган кыйссаларында, вакыйганы алып бару өчен уңайлы дип табылган чара булып файдаланыла. К. Насыйри кыйссаларының текстларында *-р иде* формасы рәттән диярлек тезелеп бара. «Кырык вәзир кыйссасы»ның (1868) барлык хикәятләре дә, нигездә, бер төрле штамп белән башлана: ...Wәзир әйтде: Җиһан сарайында бер патша бар иде. Аның ике wәзире бар иде. Бере бик ғалим wә бере бик надан иде. Бер көн надан wәзир әйтер иде. ...дийәр иде, ...бу сүзләр патшаға хуш күренер иде... [Насыйри, 1975, б. 225] һ.б. Әлеге җөмләләрдә *-р иде* формасындагы аналитик үткән заман хикәя фигыле фикер әйтүче (хатын, вәзир) күреп торган хәлләр, үткәнгә күчерелеп әйтелүе белән, хәзерге татар әдәби телендәге *-а иде* формасының синтагматик, ягъни үткәндәге даими, гадәти эшләрне белдерә торган мәгънәсе белән кулланыла кебек. Шуның белән бергә, сөйләү моментыннан алда булган эш-хәлнең агышын үткәннең билгеле бер вакытында булуы искәртелгәндә, *-а иде* фигыленең парадигматик мәгънәсенә дә туры килеп кулланылуы аңлашыла: ...Хатын әйтде: Қадим заманда бер олы патша бар иде wә аның йанында бер кеше бар иде. Һәркайчан патшаға әйтер иде: И патша, кирәк йахшылық, кирәк йаманлык – һәр ни эш қыласың, үзеңә қыласың, – дийәр иде. Патша аны ғайәть сөйәр иде... [Насыйри, 1975, б. 234] һ.б. Һәрхәлдә, кеше сүзен сөйләп хикәяләнә торган кыйссаларда *-р иде* формасының тәгаен генә нинди мәгънә белдерүенә караганда, шартлы сөйләүче тарафыннан, аңа алдан ук билгеле булган хәлләрне укучыга бәян итүдә уңайлы бер алым булуы

мөһим санала, *-ды* кушымчалы билгеле үткән заман фигыле әлеге күрү ноктасын конкретлаштыра.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда да (1881) *-р иде* күрсәткечле үткән заман хикәя фигыле, асылда, шушы ук мәгънәсе белән файдаланыла. Тик монда «хатын әйтде», «вәзир әйтде» штампы булмаганга, вакыйганың хәбәр сөйләүчеләр һәм әсәр күчерүчеләрнең сөйләме дип, ягъни III заттан бирелүе авторның үзе тарафыннан белдерелә: Ривайәне әхбар wә нақыйләне асар ошбу тариқ үзрә ривайәть қыйлыр ки, ...мәҗлесләрдә wә сохбәтләрдә фәһем wә фирасәте белән wә үткәнлеге белән қылны қырыққа йарыр иде [Насыйри, 1974, б. 208]. Кыйссада бара торган вакыйга-хәлләрнең гомум мәгълүм булуы әледән-әле искә төшерелә тора: Хәтта хикәйәт қыйлыныр ки, мәктәптәге сабақ балалары үз араларында, моның зирәклеген бәхәс қыйлышып сөйләшерләр иде, wә ...утыра торған җурғаны астына бер табақ кәғазь салып қуйарлар иде. Әбуғалисина килеп утырғач, ғаҗәпләнеп, мәктәпнең бер түшәменә, бер идәненә қарар иде. ...астында бер табақ қәғазь барын сизәр иде... [Насыйри, 1974, б. 209] һ.б. Менә шул рәвешчә, һәр җөмләдә *-р/-мәс иде* формасы кулланыла, хәзерге әдәби телдәге *-а иде* тәмамланмаган үткән заман фигыленең мәгънәләре кебек, үткәндә булган хәлләрнең тыңлаучыларга (укучыларга) кабатланып сөйләнүе аңлашыла. Күрү ноктасы *-ды* кушымчалы фигыль белән ныгытыла бара: Халық боларны кисәктән күреп, ғайәть қурқыштылар [Насыйри, 1974, б. 213] һ.б. Эш-хәлләрнең күптән үткәнлеге, әмма сөйләү моменты белән бәйләнеше булуы *-ган иде* фигыле белән тәгаенләнә: ...аларның йаwызлықларыннан халық ғаҗиз булғаннар иде, wә аларның фетнәсеннән қотылмақта чарасыз қалғаннар иде [Насыйри, 1974, б. 213] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1879) әсәренең тезмә өлешендә *-р иде (ирде)* формалы фигыль кулланылмый, ә чәчмә өлешендә хикәяләүне алып баруда эзлекле файдаланыла: ...һәрwақыт күңеленә бераз қайғу wә тарлық килүр иде. Қайсы вилайәтдә wә қайсы шәһәрдә...илчеләр wә сансыз алтынлар wә көмешләр күндереб алдырыр ирде, ...дәwалар йасатыб ашар ирде,... қайғулары қуанычқа алмашынур иде, ...күңелен ачуб китәр иде... [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 2–3] һ.б.

Гомумтюркологик пландагы тикшеренүләрдә *-р иде* формасының төп мәгънәсе эшнең тәмамланмаган, билгеле, типик һәм тасвири булуын күрсәтә [Юлдашев, 1965, б. 137–147].

Әлеге билгеләмәдә *-р иде* формасының үткәнне тасвирлау өчен уңайлы булуы дигән фикер алда китерелгән мисалларның эзлекле булып кулланылышында чагылыш табуы белән расланды. Автор үз сүзен үз исеменнән сөйләп хикәяләнә торган татар прозасының икенче төрендә язылган әсәрләрдә *-р иде* формалы үткән заман фигыленең тәмамланмаган, билгеле, типик, тасвирый булу вазифасы белән файдалануы аңлашыла. Бу төр хикәяләү М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романы белән башлана. Хәбәр сөйләүче һәм әсәр күчерүчеләрнең сүзен кабатлап сөйләү алымы юкка чыга, вакыйга-хәлләрне автор үз карашыннан, үз исеменнән сөйләп алып бара: Русия уртасында Идел нәһерендән озақ дәгел бер татар аwылы мәүҗүддер. Каръйанең әһалисе ике йөз қадәрү улыб, адыны фаш итмәкдән чикенейүрез, анчақ хикәйәмези йиңел аңлатмақ ичүн адыны «Н» хәрфе илә ишарәт итәмез... [Акъегет, 1886, б. 2]. Авылның кайда урнашканлыгы, аның мәчете, урамлары искә алынып, кешеләренең кайда, ничек эшләүләре турында әйтелгәч, аларның автор үзе күргән, белгән үткән хәлләрен хәзергә күчереп, эш-хәлнең тәмамланмаган, билгеле булуын тасвирлап сөйләү дәвам ителә: Бу ханә үзе кечек булса да, тахтадан башы, анбары вә мәхкәм сарайлары сахибенең иҗтиһадлы wә хезмәт сәвән адәм идекене күстәрерләр иде. Бу ханәдә менла қадыны тол Зөлхайа wә уғылы Хисаметдин менла адлы адәмләр торырлар иде... Хәзердә кәндүсе ханәсенең икенче бүлмәчегендә сабыйлара дәрес вирер иде. ...әмма чуқ адәм менлаи йахшы белмәдекләрендән сәүмәзләр иде [Акъегет, 1886, б. 2–3]. Әлеге җөмләләрдә *-р/-маз иде* формалы хикәя фигыльләр белән эш-хәлләрнең үткәндә булган, тәмамланмаган, авторның, димәк укучының да күз алдында дәвам ителүе күрсәтелә. Җентекләгәндә, бу фигыльне төрле мәгънәләренә бүлеп карарга мөмкин, әмма аларның барысының да автор карап, күреп торган яссылыкта баруы аңлашылачак.

Автор үз сүзен сөйләп хикәя иткәнгә күрә, *-р иде* формасы, хәзерге татар әдәби телендәге *-а иде* күрсәткечле фигыльнең парадигматик мәгънәсе кебек, билгеле бер вакыт белән чикләнгән, үткәндә булган эш-хәлләрне дә аңлата: Йәшь әфәнде чуқдан бу кеби кеше илә таныш улмақ эстәйүр иде [Акъегет, 1886, б. 8]; Менла мөсафирханәйә кердеке әснада, Хәнифә туташ мәзкүр кечек бүлмәдә ойық туқып утырыр иде [Акъегет, 1886, б. 10] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, чиксез фигыльләрдә (эстәйүр, төшәр) эшнең дәвамлы булуы, чикле фигыльләрдә (утырыр, ирешер (наил) эш-хәлнең кабатлануы белдерелә.

*-р/-маз иде (ирде)* формалы үткән заман хикәя фигыль гадәти, кабатлаулы, теге яки бу персонажның характерына хас булган эш-хәлләрнең атамасы буларак та кабатлана: Менладан мәсаиле шәрғыйә сорарлар иде, чөнки Хисаметдин менла башқа менлалар кеби, киртек-миртек җаwапланмаз иде, туғры wә хақыйқать җаwап вирер иде [Акъегет, 1886, б. 11] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, бу әсәрдә *-р иде* формасы, *-йур иде* күрсәткечле үткән заман фигыле белән үзара чиратлаша башлый. Ике кушымчаның да элек үткән, әмма автор карашыннан, хәзер дә дәвам итүе сизелә торган мәгънәләре белән кулланылуы күренә. *-йур иде, -р иде* формалары гомумтюркологик планда язылган хезмәтләрдә, билгеле бер дәрәҗәдә, аерылып карала һәм мәгънә эчтәлекләрендәге үзенчәлеккә игътибар ителә: «...Отличительным признаком этих двух форм является единичность или типичность обозначаемого действия: в отличие от формы на *- йор иди- (-йорды-)* форма на *-ар эди- (-арды-)* характеризует обозначаемое ею действие как типичное; форма же на *-йор эди-, -йорд*ы характеризует действие как единичное», – дип аңлатыла [Юлдашев, 1965, с. 143].

М. Акъегет романында *-р иде* һәм *-йур иде* формаларының мәгънәләре аерымлана дип әйтеп булмый. Билгеле бер контекстта әлеге ике форма да гадәти, даими, тәмамланмаган, дәвам итәлә торган эш-хәлләрне аңлата. Югарыда китерелгән мисаллардан башка, тагын түбәндәге җөмләләргә игътибар итәргә мөмкин:... әмма чуқ адәм менлаи йахшы белмәдекләрендән сәүмәзләр иде, мәсәлән, карьйаның указный менласы қарт Бикбулат менла әфәнде Әхмәтша уғылы, хәсәдлек итеп, аны сәүмәйүр иде wә мәхәлләсенә дийүр иде [Акъегет, 1886, б. 3]. Икенче бер урында *-р иде* һәм *-йур иде* формалары икесе дә билгеле бер вакыт белән чикләнгән арада булган эш-хәлләрне белдерә: ...Гәрчә бер хезмәтче тотса да wә чуқ дәфға йаз wақыты иген эшендә башқа хезмәтчеләр йалласа да, әксәре үзе дә қара иген эшене эшләйүр иде [Акъегет, 1886, б. 4].

Шулай итеп, М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында *-р/-маз иде* кушымчалы үткән заман фигыленең *-йур иде* күрсәткечле фигыль белән чиратлашуы, мәгънәне аерымлау максатын күздә тотмыйча, авторның традицион-угыз формасын файдалануын күрсәтү чарасы буларак кулланылышка кертелүе аңлашыла. *-йур иде* күрсәткечле фигыльнең әлеге вазифасы башка мәгърифәтчеләрнең иҗатында да дәвам итәлә, әмма аерым үзенчәлекләр дә күренә.

З. Бигиев «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887) әсәрендә үз исеменнән I зат күплектә сүзен башлый да, хикәяләүне алып бару өчен уңайлы булган *-р иде* формалы фигыльләрне файдаланып дәвам итә: Хикәйәмез гаҗәйеп гүзәл хикәйәдер. Хикәйәмези йахшы аңлатмаķ өчен әүwәлән вокугасы нә йирдә wә нә wаķытда улдығыны йазамыз... Җәмәғатьнең мөбәйенләрендән бу кеби сүзләр ишетелер иде. ...Җәмәғать телендән бу кеби сүзләр дә ишетеленер иде. ...Судебный пристав та мәхкәмә эчендә күренер иде [Бигиев, 1887, б. 2–3]. Авторның карашыннан эшнең тәмамланмаганлыгы аңлашылып, аның дәвам ителүе тасвир ителә. *-р иде* формалы фигыль, хәзерге әдәби телдә *-а иде* фигыленең парадигматик мәгънәсе кебек, ешрак чиксез фигыльләр белән бергә килеп, эш-хәлнең агышын белдерә. *-йүр иде* формалы фигыльнең бер мәртәбә башкарылган эшне белдерү өчен кабатлануы күренә: Нумерләргә мәķтүлә хатын хосусында тәфтиш өчен кәләйүрләр иде [Бигиев, 1991, б. 221]; ...Хәдичә туташ Муса әфәндине күрмәк эстәдекендән, тәхтәләр арасындан ярык эзләйүр иде [Бигиев, 1991, б. 231].

«Гөнаһе кәбаир» романында (1890) *-йүр иде* формалы фигыль дәвамлы, кабатлаулы эш-хәлләрне дә белдерә: Көнләр ғадәтчә кәчәйүрләр иде [Бигиев, 1991, б. 247]; ...һәр көн дамелла дәрескә керер wаķытда гына эчәйүр иде [Бигиев, 1991, б. 277] һ.б.

Шул ук мәгънәне белдерү максатыннан, башка фигыльләр белән белдерә торган эш-хәлләргә җирлек рәвешендәге *-р иде* фигыле, бу авторда *-а(дыр) иде* фигыле белән чиратлаша башлый: ...Муса Салихов Хәдичә туташны кәләшлеккә аладыр иде. ...Муса әфәнде, Ниғмәтулла абзасы илә бергә сәүдә ķылып, бер өйдә торадыр иде [Бигиев, 1991, б. 223] һ.б. Аңлашылганча, «Хисаметдин менла» әсәрендә хикәяләүне алып баруда эзлекле кулланыла торган *-р/-маз иде (ирде), -йүр иде* формасы, З. Бигиев әсәрендә дәвам ителгән хәлдә, *-адыр иде* күрсәткече белән чиратлаштырыла. Әлеге күрсәткечле фигыльнең бу вазифасы авторның «Гөнаһе кәбаир» романында (1890) дәвам ителә: Мәкәрҗә базарында да байны зийарәт ķыйладыр иде [Бигиев, 1991, б. 258]; ...дүртесе бер өйдә икамәт идәйүрләрде [Бигиев, 1991, б. 259]. Мисаллардан аңлашылганча, *-р иде* күрсәткечле фигыльнең *-адыр иде* формасы белән алмаштырылуы авторның вакыйганы күреп торуын тагын да көчәйтә кебек.

«Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» (1908) юлъязмасы I заттан язылганга күрә, хикәяләүне III заттан алып бара торган

*-р иде/-ырды* формасына караганда, *-р* һәм *-йур* формалы фигыльләрнең хәзерге заманны белдерә торган мәгънәсе ешрак файдаланыла, ягъни аларның кулланылышына, авторның кайсы укучыны күздә тотып язуына нигезләнгән жанр-стильләрнең таләбе үзенчә тәэсир итә.

Бу төрдәге мисаллар Ф. Кәрими һәм Р. Фәхретдин әсәрләрендә дә күзәтелә. «Морза кызы Фатыйма»да: ...Фатыйма кеби тәрбийәле wә кибар бер қызға қаршы үзенең кальбен ачарға аслан җәсарәт итә алмайынча, кичә wә көндез мәхбүбәсенең тасвир wә хыйалы илә wақыт кичерәйүрде [Кәрими, 1996, б. 89]. «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә: Wә қыйраәтханәсендә Русийәдә чыққан һәртөрле мөғтәбәр газеталардан магада французча, немесчә газеталар дәхи булынайурды [Кәрими, 1996, б. 159] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә *-йур иде* формасы, нигездә, бер мәртәбә була торган эш-хәлне аңлата: Хикмәт хаҗи бишенче қызыны йаңа указ алмақда улан Ғаббас мелла сорамақында һич шөбхә итмәйүр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 315]; ...сызланып йатмақда улан қартлар урынларындан сикереп тордықдарыны белмәй қалырлар wә «Һай, үзәкләрем өзелә...» дийүрләр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 318]. һ.б.

Шулай итеп, XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган текстларда *-р иде* һәм *-йур иде* формаларының мәгънә аерымлануы – аерымланмавы билгеле бер дәрәҗәдә күзәтелсә дә, бу чорда әлеге формаларның функциональ кулланылышы әһәмиятлерәк булып күтәрелә: *-йур иде* формасы үз чоры әдәби теленең госманлы варианты белән язылган текстларда киң файдаланыла һәм халыкчан вариант белән язылган текстларга каршы куела. Ф. Кәрими иҗатында бу таләп тагын да сизелерлек булып чагыла. Татар укучысына аның үз тормышы сурәтләнеп языла торган хикәяләренең теле дә сөйләмә телгә якынайтыла. «Салих бабайның өйләнүе» (1897) хикәясендә, *-р иде* формалы фигыльгә караганда, *-а иде* формасының III зат күплек формасы эш-хәлләрнең дәвамлы булуын белдерә торган мәгънәсе белән ешрак кабатлана: ...Бик ақрын ғына искән қыйбла җиле илә ағачларның йафрақлары җилбер-җилбер итеп қыштырдашып торалар иде, ...арбаға сыйа алмағач, бәғзеләре арба артыннан җәйәү киләләр иде, ...чегән күз буып, үзе теләгән нәрсәне алып китә дип алдашалар иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224] һ.б.

*-р иде* формалы фигыль, шартка бәйле рәвештә кулланылып, гепотетик (мөмкин булган) эш-хәлләрне белдерү вазифасы белән

файдаланыла: ...Ихтимал ки, без булмасаҡ, болар чегәннәрдән ҡурыҡҡан да булырлар иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 225]; ...Йахшылабраҡ ҡарасам, бу ир бала, ...төсенә-ҡыйәфәтенә ҡарағанда ҡызның ҡардәше булырға биңзидер иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 226]. Бу әсәрдә эзлекле рәвештә *-адыр иде* формалы фигыль кабатлана, *-а торган иде* формасы кулланылыш ала [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 220–229]. «Бер шәкерт илә бер студент» (1899) хикәясе I заттан сөйләп языла, димәк, вакыйга барышы күрелеп үткән *-ды,* нәтиҗәле *-ган* кушымчалы фигыльләр белән бирелә, хәзерге заман *-а,* тәмамланмаган үткән заман *-а (дыр) иде* формалары файдаланыла: ...пароходына кердем, ...йалтырап койаш чыккан. ...Болар бик ашығып пароходка керәләр иде. Күпер өсте бик тығызлык, ҡайсы керә, ҡайсы чыға... [Кәрими, 1996, б. 30–31] һ.б.

Тәмамланмаган үткән заман *-р иде* формасы, киләчәккә каратылып, укучыга мөрәҗәгать итү өчен файдаланыла: ...сез булсағыз нишләр идегез, ...марҗадан ғафу сорар идегез, ...пароходҡамы туры кереп китәр идегез [Кәрими, 1996, б. 31–32]. «Морза кызы Фатыйма» (1901) әсәрендә дә, әлеге алым күзәтелә: ...бу арзусыны сез, әлбәттә, йиренә китерер идеңез [Кәрими, 1996, б. 84]. Бу әсәрдә Кырымда бара торган вакыйга хикәяләнә, шуңа күрә дә, авторның алда искә алынган әсәрләрендәге кебек *-а иде, -адыр иде, -мыш иде, -ган иде, -макда иде* формалы үткән заман фигыльләре белән рәттән, *-йур иде* күрсәткечле фигыль дә күзәтелә: ...кичә вә көндез мәхбүбәсенең тасвир wә хыйалы илә wаҡыт кичерәйүрде [Кәрими, 1996, б. 89]; ...мең тәсауверләргә талып, күзләрендән уйҡусы ҡачыйур иде [Кәрими, 1996, б. 90], ...wатан wә бакча мәхәббәтеннән дәха зийадә шөтдәтле тәэсир итәйүр иде [Кәрими, 1996, б. 192]. Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә *-йур* кушымчалы фигыльнең хәзерге заманы эзлекле кулланыла. Шулай итеп, татар прозасының үз сүзен сөйләп иҗат итүче мәгърифәтче әдипләребездә *-р иде* формалы үткән заман хикәя фигыльне куллану кыйссалардагы шикелле штампка әверелми: һәрберсенең әсәрендә билгеле бер үзенчәлек чагылыш таба. Әйтеп үтелгәнчә, XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган текстларда, үткән заман хикәя фигыльнең синтетик төрләрендәге кебек үк, аның аналитик формаларында да, авторның теләге һәм аерым жанр-стильләр таләбенә җавап бирү максатыннан, эш бүленү күзәтелә.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1898) әсәрендә: ...Wаҡытларның берендә бу хөрмәтле затлар мәҗлесендә улачаҡым хыйалы

илә шатланып, бу шатлыкның тиз заманда улуны җаным эстәр иде. Хальбуки җаным эстәдеке қадәр йөрәгем қурқыр иде... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 275] кебек өзекләр бирелсә дә, яисә «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) әсәрендә: Ғаббас мелла, белер өчен ғайрәтле улдығы кеби, белдекләре илә һәм ғамәл қылыр иде. Вәғазьләрене йомшақ сөйләр, мисалларыны ачық күстәрер, ислам қағыйдәләрене ғаwам халқына саф wә ап-ачық аңлатыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 290] кебек җөмләләр күзәтелсә һәм бу юнәлештә *-р иде, -а иде* кушымчалы фигыльләрнең бертигез дәрәҗәдә файдаланылуы күренсә дә, әмма әсәрләрдә бара торган вакыйга-хәлләрне алып баруда төп чара булып *-макда иде* формасы сайланган. Шул ук *-макда иде* формасы Ш. Мөһәммәдевнең «Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай» хикәясендә файдаланыла. Әлеге әдипләрнең әсәрләрендә *-р иде* формасының киләчәк заман мәгънәсендә һәм шартлы теләкне белдерә торган мәгънәсе белән дә кулланылуы күзәтелә.

*-р иде* күрсәткечле тәмамланмаган гадәти-тасвирый үткән заман хикәя фигыльнең үзенчәлекле кулланылышы классик әдипләребез иҗатында да дәвам ителә. Аның төп үзенчәлеге булып, барлык әдипләрдә дә диярлек, әлеге форманың шул ук мәгънәдә кулланыла торган *-а иде* формасы белән тулаем алмаштырылып бетүе санала ала. Шулай итеп, *-р иде (ирде)* формасының татар чәчмә әсәрләрен хикәяләүдә билгеле бер эволюция кичерүе чагылыш таба дип әйтә алабыз.

*-а (дыр) иде* формалы үткән заман хикәя фигыль *-р иде* кушымчалы фигыльдән соңрак гамәлгә куела, К. Насыйриның сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә күзәтелми диярлек. Мәгълүм булганча, автор «Әнмүзәҗ» китабында *-а (дыр) иде* формалы фигыльне искә алмый, әмма фәнни хезмәтләрендә сирәк кенә булса да, әлеге фигыльне файдалана: «Мәғлүм ки, ошбу заманымызға қадәр махсус лисанымыз өчен бер сарыф wә нәхү қагыйдәләрен бәйан қыйлғучы бер китап тасныйф қыйлынғаны күренмәйдер иде. Утыз, утыз биш йылдан бирле ике тел фәнләрендән, йәғни үз телемездән wә дәхи рус телендән балаларға сабақ уқытқанда, үз телемезнең қағыйдәсен бәйан қылғучы бер китабқа мохтаҗ буладыр идем» [Насыйри, 1895, б. 3]. Сәнгатьле проза текстлары белән чагыштырганда, фәнни хезмәтләрдә, *иде* ярдәмлеге белән ясалган үткән заманнар гомумән чикле. Бу күренеш аналитик фигыльләрнең чыннан да, асылда, тасвирлау чарасы булырга кулайрак икәнлеген раслый.

Әйтеп үтелгәнчә, З. Бигиев романнарында *-р иде* чиратлашуы белән бара торган сөйләп хикәяләүдә *-а (дыр) иде* формасы да

кабатлана башлый. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында: Муса Салихов Хәдичә туташны кәләшлеккә аладыр иде. ...Муса әфәнде, Ниғмәтулла абзасы илә бергә сәүдә қылып, бер өйдә торадыр иде [Бигиев, 1991, б. 223]; ...Газизем, сез мәқтулә Зөләйханы хале хәйәтендә беләдер идеңезме? [Бигиев, 1991, б. 225]; ...нә хәбәр илә кәлер икән дәйү, господин Шубинны көтәләр иде. ....Ғабдуллин нумирләрендә, 9 нумирдә торадыр иде [Бигиев, 1991, б. 227]. Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, *-а (дыр) иде* формалы үткән заман хикәя фигыль тәмамланмаган, гадәти, күрелеп үткән-тасвирый мәгънәсе белән кулланыла. «Гөнаһе кәбаир» романында да *-а (дыр) иде* фигыленең, нигездә, «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендәге мәгънәсе реальләшә, ягъни үткәндәге билгеле бер вакытында булган, тәмамланмаган, гадәти-типик, күрелеп үткән-тасвирый мөмкинлеген күрсәтә: Түгел арақы эчәргә чәйне дә ул wақытта бик аз кешеләр беләдер иде [Бигиев, 1890, б. 6]; Менә күбдән түгел бер хатын кәлеб, бу қарчықның өендә бер-ике җомға қунақ булған иде... хәер бик гизли торды, һич дә өй эчендән чықмый иде [Бигиев, 1890, б. 43] һ.б. Әлеге мәгънәнең реальләшүенә лексик чаралар да ярдәм итә. З. Бигиевнең сәяхәтнамәсендә *-а иде* формалы фигыль кулланылмый диярлек.

Татар прозасындагы *-а (дыр) иде* үткән заман хикәя фигыле Ф. Кәрими иҗатында тагын да активлаша, сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә вакыйганы алып баруда төп көчкә әверелә, әлеге форманың бигрәк тә I зат берлектәге һәм III зат берлек һәм күплек саннары еш кабатлана. «Салих бабайның өйләнүе» (1897) хикәясендә: Бу қартны мин бик сөйәдер идем. Мин йәшь wақытымда бер хәзрәтдә хезмәтдә торадыр идем....Бу қызларға очраған wақытда, күрше аwылдағы бер тутамызға қунаққа барадыр идек [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 290] һ.б. Әлеге мисалдан аңлашылганча, *-а (дыр) иде* формасы, һәр өч затның да кушымчаларын алып, үткәндәге билгеле бер вакыт эчендә булган, хәзер дә тәмамланмаган, башка эш-хәлләргә фон булып тора торган мәгънәсе белән кулланылуы аңлашыла. Шушы ук мәгънәсе белән *-а (дыр) иде* формасы авторның башка әсәрләрендә дә файдаланыла: ...абыстай да Җиһангир мәхдүмне бик сөйәдер иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 230]; ...қарындық қуйалар иде, ...хәстәләнергә башлыйлар иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 231] һ.б.

Шуның белән бергә, *-а (дыр) иде* формалы үткән заман, киңәйтелгән хәзерге заман мәгънәсендә, ягъни гадәти, типик, кабатлаулы эш-хәлләрне белдерү мәгънәсе белән дә файдаланылуы күзәтелә:

«Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә: …хикәйәт сөйләргә башлау белән, ике қолағыбызны дүрт итеп, ғайәть диққать белән күнел биреп тыйңлыйдыр идек; ...барадыр идек; ...ақрын ғына киләдер идек [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 224] һ.б. «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» әсәрендә: атасының қаләм wә қара саwытыны алып, туғыры килгән кәғазь өстенә төрле-төрле сызықлар wә сығыр сурәте кебек нәрсәләр йасап маташадыр иде... һ.б. «Морза кызы Фатыйма» әсәрендә: ...Қара диңгез суларының йарларға бәрелеп китқәнен сәйер wә тамаша итеп, сәғатьләрчә wақыт кичерәдер иде [Кәрими, 1996, б. 81]. Фатыйманың кибар бер Морза қызы булуын, wә үзләренең ғади бер мужик баласы булуын хисаплағанда, татлы хыйалларның барысы да ачы бер қайғы-хәсрәткә әйләнәдер иде [Кәрими, 1996, б. 82] һ.б. Гадәти-типик мәгънәне белдерә торган *-а (дыр) иде* формасының бик җинел генә (янәшә җөмләдә) *-а торган иде,* яисә *-макда иде* формасы белән чиратлашуы күзәтелә.

Ф. Кәриминең сәнгатьле проза әсәрләрендә *-а (дыр) иде* формасы сөйләү моментында булып тора торган эш-хәлләрне аңлата торган мәгънәсе белән дә файдаланыла. Бу хәл бигрәк тә авторның беренче заттан хикәяләнә торган әсәрләрендә, яисә өченче заттан хикәяләнгән очракта персонаж сөйләме итеп бирелә торган абзацларда ачыграк күзәтелә. «Салих бабай»да: Тавышының нечкәлегенә wә татлылығына қарағанда, хатын-кызлар тавышы булырға охшыйдыр иде. Йахшылабрақ қарасам, бу ир бала әүwәлге көн қызлар илә бергә җиләктән қайтқан уғылан булып, төсенә-қыйәфәтенә қарағанда, қызның қардәше булырға биңзидер (охшыйдыр) иде [Кәрими, 1901, б. 24] һ.б. «Җиһангир мәхдүм»дә: Хәзрәт быйыл дәхи қыйраәт иттермәкче булып торадыр иде. Хальбуки йегетләр илә қызлар күрешәләр дип, Әхмәтша хәзрәтнең сабан туйы йасарга бер дә рөхсәт бирәсе килмидер иде, тырышуы арта барадыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 245] һ.б.

Китерелгән мисал-өзекләрдән аңлашылганча, *-а (дыр) иде* формалы үткән заман хикәя фигыль сөйләү моментында бара торган эшхәлләрне аңлаткан вакытта *-а* формалы хәзерге заман һәм *-ды* кушымчалы билгеле үткән заман фигыльләре белән бергә чиратлашып кулланыла. «Бер шәкерт илә бер студент» хикәясендә: ...ашығып-ашығып, һәр йақтан төрле-төрле кешеләр киләләр. ...берничә рус wә рус хатынлары, ...конторның күперендән керәләр иде, ...үзләре артдан киләләр, ...ак җиләннең күкрәгендә берничә җирдәге кап-кара таплар бик йырақдан

айырмачық күренеп торадыр иде, ...үз урыныма килдем, хәзрәткә күз салдым, хәзрәт Қоръән уқыйдыр иде [Кәрими, 1996, б. 35].

Ф. Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902) һәм «Кырымга сәяхәт» (1904) юлъязмаларында *-а (дыр) иде* формасы бөтенләй диярлек күзәтелми. Автор үзе күреп торган хәлләрне сөйләгәнгә күрә, хикәяләү *-ды* формалы билгеле үткән заман белән бара, аналитик үткән заманнардан *-йур иде* [Кәрими, 1996, б. 166], *-макда иде* [Кәрими, 1996, б. 169, 175], *-мыш иде* [Кәрими, 1996, б. 190] формалары файдаланыла.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1899) һәм «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) романнарында вакыйга, асылда, *-р иде, -макда иде, -мыш иде* формалары белән хикәяләнә, әмма *-а иде* формасы да файдаланыла. «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә эш-хәрәкәтнең тәмамланмаган, эзлекле булып баруын белдерү өчен, рәттән, *-р иде, -макда иде* формасы кулланыла торган җөмләләр *-а иде* кушымчалы җөмлә белән дәвам ителә: ...Бәңа йырақ дәгел урында ике хатын сүзләшүенә қолақ салып гаҗәп итдем, чөнки бунлар франекчә киендекләре хәлдә фарсыча сүзләр иделәр, ...урын йуқлығындан шиқайәть идәрләр иде [Фәхретдин, 1899, б. 16]. *-а иде* фигыленең мәгънәсен, *-р иде* фигыле белдерә торган мәгънә белән бердәй, аларны алмаштырып әйтергә мөмкин дип уйларга була, әмма *-а иде* формалы фигыль белән белдерелә торган хәлне кабатлап булмавы аңлашыла.

Шуның белән бергә, *-а иде* күрсәткечле фигыльләр белән искә төшерү, гөманлауны белдерә торган хәлләр дә бәян ителә: ...олуғ ағач саwытлар лә қымыз эчүләремне фикерләп, аwызымнан сулар аға иде, ...сандуғач сайрауларыны дыңлап ләззәтләнәчәк көннәрем вар идекене фикерләп, балалар мисалендә сәвенә идем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 269] һ.б. Р. Фәхретдиннең бу әсәрендә бер мәртәбә *-дем иде* формалы фигыль кулланыла: Сәлимә туташның тыныч урынға ихтыйаҗы варлығыны ачық белдем иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 275]. «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә хикәяләүне *-р иде* формалы фигыль алып бара: һәр абзац рәттән диярлек *-р иде* яисә *-мас иде* формалары белән тәмамлана, вакыйгаларны хикәяләүдә үзенчәлекне бер ритм хасил була, *-макда иде* формасы сөйләнә торган хәлләрнең мenә хәзер, укучы күз алдында бара кебек тәэсирен көчәйтә, әлеге максаттан сирәк кенә *-йур* формалы фигыль кулланыла: ...һич шөбһә итмәйүр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 315]; ...шуңар мәҗбүр уларақ ағлайурым [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 324], ...вәғазь ит-

мәгә тырышыр, ләкин муафыйқ улмайур иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 327] һ.б., үткәндә булган эш-хәлләр *-мыш иде* формасы белән белдерелә, *-а иде* формалы үткән заманның кулланылуы күзәтелми.

Г. Исхакыйның Р. Фәхретдин әсәрләре белән бер үк вакытта диярлек басыла башлаган беренче хикәяләрендә дә *-а иде* формасы, нигездә, искә төшерү, хәтерләү рәвешендә бирелә торган өлешләрдә кулланыла. «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер»дә (1899): Хәлим... үзенең элгәреге хәлләре берлә үлчәп әйтә: «Мин кечкенә бер малай идем. Малайлар арасында уйнап йөри идем, алай булса да, аwылымызда мәдрәсә ачылғач да, барып сабақ уқый идем. Мәктәптә сабағымны белгәнгә, мулла абзый да ярата иде, әтигә мине һәрwақыт зуррақ мәдрәсәгә илтергә қуша иде. Әти дә, үзенең байлығы булса да, расхут күп булыр дип, мине мәдрәсәгә илтүдән курқа иде»... [Исхакый, 1998, б. 43]. «Кәләпүшче кыз» (1900) хикәясендә: Ғабдерәшитне искә төшереп: Мондан бер ай элгәре әтиеңез сәләмәт иде, қулымыз иркен иде. Чәй эчкәндә бер сезгә қарап, бер мине қарап рәхәтләнеп көлешеп утыра идек, ғомеремезнең, дөньйаға килүемезнең рәхәтен күрә идек... [Исхакый, 1998, б. 54]. Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, *-а иде* формасы белән тезелеп бирелә торган фигыльләр искә төшерү хәлләрен сурәтләү өчен кулланыла, шул ук вакытта, әлеге форманың төрле мәгънәләре дә реальләшә: үткәндә булган, сөйләү моментында актуаль, кабатланып тора торган, үткәннең билгеле бер чорына караган (малай чакта һ.б.), билгеле бер эш-хәлләрнең үзара бәйләнеше мәгънәсендә (сабагымны белгәнгә, ярата, дөньяга килүнең рәхәтен күрү һ.б.).

Г. Исхакый әсәрләрендә *-а иде* формасы сөйләү моментында, сөйләүченең күз алдына бара торган эш-хәлләрне белдерү өчен дә бик актив файдаланыла: «Кәләпүшче кыз»да: Нечкә пәрдә арқылы Мифтах абзыйның өй эчләре күренә иде. Өйләре матур иттереп зиннәтләнгән, түр башында Кәримә абыстай намаз уқый иде. Васфибану киенгән-йасанған – кийәwен көтә иде, ...манзарәләре бирүдә иде [Исхакый, 1998, б. 68]. «Бай угылы»нда (1903): Қарчықлар да қулларыннан килгән хезмәтләрене итүдә иделәр: ...ләкин шунысы ғаҗәп, бала һаман дөньйаға килми, Сәғыйдә бикә аwырғаннан аwырый иде [Исхакый, 1998, б. 114]. Г. Исхакыйның барлык әсәрләреннән дә *-а иде* формалы фигыльнең төрле мәгънәләре белән кулланылуына күп мисал-өзекләр китерергә мөмкин, чөнки бу әдипнең әсәрләрендә бара торган вакыйга-хәлләрне нәкъ менә шушы формалы фигыльләр алып

бара. Шулай итеп, Ф. Кәрими иҗатында активлаша башлаган *-а иде* формалы фигыль бу әдипнең иҗатында төп көчкә әверелә, традицион язма *-р иде* үзенең башка мәгънәсе белән (шартлы теләк) файдаланыла, *- макда иде* бөтенләй кулланылмый. Сөйләү моментында бара торган эшләрне белдерүдә файдаланыла торган *-а иде* формасы, төрле әсәрдә төрле дәрәҗәдә *-уда иде* формасы белән алмаштырып дәвам итәлә, *-а иде* формалы фигыльләр һәр әсәрнең темасына, персонажлары характерына һәм аларга карата автор мөнәсәбәтенең нинди булуына бәйле рәвештә, әсәрнең тел тукымасы өчен кирәк булган ритм-көй (моң) бирүгә җайлаштырыла. Мәсәлән, «Зиндан» повестенда бер үк сүзләрнең, сүзформаларның кабатлануы төрмәдә тормышның тукталганлыгын, сүлпәнәюен тасвир итә, *-а иде* формалы фигыльләр сөйләү моментында да дәвам итә торган, тәмамланмаган, күренеп үтә торган эш-хәлләрне аңлата.

«Тормышмы бу?» (1911) романы да, асылда, вакыйгаларны сурәтләү нигезе белән «Зиндан»га охшаш, әлеге әсәрләрнең һәр икесе дә беренче заттан хикәяләнә. Монда да шәхеснең чынбарлыктагы сазлыкка батуы, «...тормышның комғаннары, чиләкләре, мал-туары, көндәлек мәшақатьләре, ызғыш-талашлары эченә кереп батуы, хыяллары җимерелүе» сурәтләнә [Исхакый, 1991, б. 643]. Шулай да бу төрмә түгел, монда тормыш туктамаган, шуңа күрә дә типик-гадәти, кабатлаулы, сөйләүче күреп тора торган, тәмамланмаган мәгънәләре белән кулланыла торган *-а иде* формалы фигыльләр хәбәр булып килә торган җөмләләрдә тиңдәшләнеп килүче кисәкләр күбрәк, *-а иде* күрсәткечле фигыль үзе сирәгрәк кабатлана [Исхакый, 1991, б. 85–86, 100 һ.б.]. Бер бер артлы тезелеп бара торган *-а иде* формалы фигыльләр «Сөннәтче бабай» әсәрендә (1911) үзенә генә хас булган ритм-көй, моң барлыкка китерә: искә төшерү, хәтер яңарту. Әлеге үзенчәлек, билгеле бер дәрәҗәдә, «Мулла бабай»да да дәвам итәлә, әмма монда *-а иде* формалы фигыльләр ешрак сөйләү моментында башкарыла торган эш-хәлләрне белдерү өчен кабатлана: бу вакытта *-а иде* формалы фигыль белдергән эш, икенче бер эшкә бәйле рәвештә, билгеле бер вакытка бәйле булырга мөмкин, бу очракта әлеге фигыльләр күбрәк *-ганда* формасыннан соң кулланыла: Ул шулай итеп торғанда, йаланда пылау пешерелә, салма хәзерләнә, аш-чәй урынлары хәзерләнә, хәзрәт wә байларның килүләренә самыwарлар өлгертелә иде... тырышалар иде [Исхакый, 1913, б. 91]. Өзектән аңлашылганча, билгеле бер вакыт эчендә бара торган эш-хәлләрнең үзара бәйле булган шартлар эчендә

үтүе күренә. Бу төрдәге бәйлелек озын абзацларда катлаулана, бәйле шартлар ераклаша, әмма барыбер тәмамланмаган үткән заманның сөйләү моментында бара торган эш-хәлләрне белдерүе аңлашыла.

*-а иде* формалы фигыль Г. Исхакый әсәрләрендә нинди генә мәгънә аңлатса да, ул, гадәттә, тиндәшләнеп килгән берничә хәбәрнең соңгысына кушыла. Үзеннән-үзе аңлашылганча, әлеге үзенчәлек тә әдипнең төрле әсәрләрендә төрлечә реальләшә.

Алга таба бу үзенчәлек, ягъни әсәрләренең рухына бәйле рәвештә, *-а иде* формалы фигыльнең кулланышы Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, М. Гафури һәм башка классик әдипләребезнең иҗатларында да колач ала. Аларның беренче хикәяләрендә кайбер традицион язма формалар дәвам итсәләр дә, вакыйганы алып баруда төп көч булып, *-а иде* формасы активлаша.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган текстларда *-р иде, -йур иде, -а иде, -а (дыр) иде* формалы аналитик үткән заманнар белән рәттән тагын *-макда иде* күрсәткечле фигыль дә кулланыла. Гомумтюркологик пландагы хезмәтләрдә әлеге форманың Урта Азия төркисеннән таралу ихтималы әйтелә [Юлдашев, 1965,б. 151].

Татар сәнгатьле прозасында *-макда иде* формасы К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда күренеп китә: ...Әбүгалисинаның ғыйльме ихфада, wә ғыйльме кимийәдә, wә ғыйльме симийәдә шөһрәте җәйелеб, wә халық арасында хикмәте сөйләнмәктә иде [Насыйри, 1974, б. 304]. Шуның белән әлеге форма үз чоры татар әдәби теленең җәдиди госманлы дип атала торган варианты белән язылган аерым авторларның кайбер әсәрләрендә активлаша. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында: Ләкин шәкерд гәд улынанлар бу җаwаби ишетмәйүб һаман қычқырмақда иделәр [Акъегет, 1886, б. 17].

М. Бигиев әсәрләрендә *-макда иде* формасы күзәтелми. Ф. Кәриминең төрле хикәясендә төрле дәрәҗәдә кулланыла. «Салих бабай»да: ...һәр нәүғы гүзәл wә ләтыйф күбәләкләр илә төрле-төрле чебенләр wә қортлар, арлы-бирле очышып, сахраның гүзәллегене арттырмақда иделәр... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 227]. Ф. Кәриминең «Морза кызы Фатыйма» әсәрендә (1901) *-макда иде* формасы, әдипнең башка әсәрләренә караганда, эзлеклерәк файдаланыла: Бу бақча морза Туғанскийның дачасына йақын бер җирдә булдығындан, морзаның кечек балалары Бәкер қартның кечек балалары илә күрешмәкдә wә уйнамақда иде [Кәрими, 1996, б. 80]. Мисаллардан аңлашылганча, *-макда иде* формалы үткән заман хикәя фигыль, асылда, күрелеп үтеп

тәмамланган башка эшләр фонында, сөйләү моментында да тәмамланмаган, сөйләүченең күз алдында бара торган эш-хәлләрне белдерә һәм шушы ук мәгънәләре белән кулланыла торган *-а иде, -йур иде* кебек аналитик үткән заман фигыльләренә синоним булып, бер генә форманы кабатлаудан котылу өчен, алар белән алмаштырылып кулланыла. Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә дә әлеге *-макда иде,* нигездә, шушы ук мәгънәсе белән файдаланыла. Мисаллардан күренгәнчә, *-макда иде* формалы фигыльләр, *-ды* кушымчалы билгеле үткән заман һәм *-йур иде* күрсәткечле үткән заманнар белән берлектә, сөйләү моментында барган тәмамаланмаган эш-хәрәкәтләрне белдерә, әлеге эш-хәрәкәтләрнең билгеле бер шарт-хәлләргә бәйле булуын күрсәтә.

Р. Фәхретдин әсәрләрендә дә *-макда иде* формасы шушы ук мәгънәсе белән кулланыла һәм эзлекле булып кабатлана. Мәсәлән, «Сәлимә, яки Гыйффәт»тә *-макда иде* формалы фигыль берничә мәртәбә кабатлангач, *-а иде* күрсәткечле фигыль белән алмаштырыла, аннан соң *-ган иде* формалы фигыль килә дә, аның артыннан тагын *-макда иде* күрсәткечле фигыль кулланыла: Йәшь балаларның көйсезләнеп йығлаулары, ана wә қараучыларның анларны йуатулары йақында пароход, йырақта улған завод wә тимер йул арбасы даwышларына қушылып, ғаҗәб рәwешдә һаваға күтәрелеп таралмақда иде [Фәхретдин, 1899, б. 14]; ...һәр wақытда хатынларны риғайа идәргә wә анларға йәрдәм wә мәрхәмәт қыйлырға тийешле, дийү мәғлүмат вирүче, wәғазь һәм нәсыйхәт қыйлучылардан һичберсе, бу зәғыйфь мәхлүкләргә үз урынларыны исар итмәзләр иде [Фәхретдин, 1899, б. 16]. Әлеге мисаллардан аңлашылганча, *-макда иде* һәм *-а иде* формалары, нигездә, бер үк мәгънәне, ягъни тәмамланмаган, күз алдында күренеп бара торган эш-хәлләрне аңлата, әмма *-а иде* формалы фигыльдә гадәтилек, типиклык мәгънәсе көчлерәк янгырый. Шуның белән бергә, Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» хикәясендә, *-макда иде* формалы фигыль аерым җөмләнең хәбәре буларак та кулланыла: Ошбу күп җәмәғать арасында берқадәр мөселман хатын wә қызлары һәм күрелмәкдә иде. Бунларның йөзләренә салған челтәр пәрдәләре, йөз wә битләренә айырмачық, ушандақ нурлы wә гүзәл идел күстәрмәкдә иде [Фәхретдин, 1898, б. 15].

Р. Фәхретдиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәре дә *-макда иде* формалы фигыльләр белән башлана, әмма «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәре белән чагыштырганда, сан ягыннан азрак кулланыла: ...Ғаббас мелланың башқа балалары улмыш исә дә, җөмләсе wафат улып,

йалғыз ошбу қыз йәшәмәктә иде [Фәхретдин, 1979, б. 312]; ...wақыты җитмәсдән моқатдәм сабақ уқыттырылмыш бала һәм имгәнеп қалмақтадыр, ...Ғаббас мелла қызы Әсмаға сабан уқымақ өчен бондан ике-өч сәнәләрдән бирү хәзерләнмәкдә иде [Фәхретдин, 1979, б. 314].

Г. Исхакый иҗатында *-макда иде* формалы фигыльләрнең кулланылуы күзәтелми диярлек. «Кәләпүшче кыз»да бер җөмлә бар: ...Кәримә: «Қызым, бәғрем, алай йығлама», – дисә дә, үзенең күзләреңдән дә йәшь ақмақда иде [Исхакый, 1998, б. 60].

Г. Ибраһимовның беренче хикәяләрендә *-макда иде* формалы фигыльләрне куллану билгеле бер дәрәҗәдә дәвам итәлә. Мәсәлән, «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә (1907): ...қапқа төбендә һәртөрле чүпләр өйелеп йата, қысқасы, шәһәрнең башқа өйләренә қараганда, бер ташландық өй кеби күренмәкдә иде [Ибраһимов, 1974, б. 400]. «Гыйшык корбанлары» хикәясендә: ...бөйекләр wә белемлеләр дә: «Кашки, балаң Сәғыйд кебек булсачы», димәкдәләр иде [Ибраһимов, 1974, б. 447]. «Яз башы» әсәрендә (1910): Теге йарның астына койаш тимәгәнгә, қаптыра торған җиребез күләнгәле һәм салқынча булып, айырым бер рәхәтлек бирмәкдә иде [Ибраһимов, 1974, б. 57] һ.б.

Шул ук вакытларда язылган З. Һади һәм Ш. Мөхәммәдев хикәяләрендә дә *-макда иде* формасы шактый сирәк кенә булса да кулланыла әле. Мәсәлән, З. Һадиның «Җиһанша хәзрәт» әсәрендә: Шул сәбәбдән Җиһанша ни булса да бер эш чықмасмы дип, бар фикерене сарыф итеп, шул мәхәләгә дүрт күз белән қарап тормақда иде [Һади, 1947, б. 431].

Мисаллардан аңлашылганча, *-макда иде* формасы, *-а иде* формасының синонимы буларак, бер үк күрсәткечләрне кабатламас өчен файдаланыла.

*-макда иде* формасы Ф. Әмирханның кайбер хикәяләрендә берәр җөмләдә генә күренгәли. «Бәйрәмнәр» дә: Садақа өләшү wә садақа алулар да шул әүwәлгечә үк иде: хәзрәтләр халыққа қарап, йаулықлар җәйеп утырғанлар, мәхдүмләр, карилар, мөсәббихлар wә һәртөрле садақачылар да, кешегә күренерлек урынларыны ишғаль итеп, һәркемнең қулына қарап утырмақталар wә ара-тирә «Алла разый булсын» дигән шикелле сүзләрне ычқындырмақталар иде [Әмирхан, 1984, б. 19]. Әлеге җөмләдә *-макда иде* формасы, рәттән тезелеп бара торган гарәп алынмалары белән берлектә, искелекне, автор тарафыннан тәнкыйтьләнә торган чынбарлыкны сурәтләү чарасы булып аңлашыла.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган сәнгатьле чәчмә әсәрләрдә, аеруча сәнгатьле проза әсәрләрендә, вакыйганы хикәяләүдә төп чара буларак файдаланыла торган *-р иде, -а (дыр) иде, -макда иде* күрсәткечле үткән заман хикәя фигыльләре белән рәттән, *-мыш иде, -ган иде, -а торган иде, -ачак иде* кушымчалы үткән заман хикәя фигыльләрнең дә эзлекле кулланылуы күзәтелә. К. Насыйри иҗатында *-ган иде* һәм *-мыш иде* формалы аналитик үткән заман хикәя фигыльләре, берсе икенчесен алмаштырып, параллель рәвештә кулланыла дияргә мөмкин. «Кырык вәзир»дә: Мәгәр патша улын, ғыйльме һәйәт wә ғыйльме нөҗүм өйрәнмәк өчен, остазға бирмеш иде [Насыйри, 1975, б. 222]; Уғыланнарын йанына чақырып әйтде: «...җәүһәр wә төрле асылташлар йәшереп қуйған идем» [Насыйри, 1975, б. 228]. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: ...ул заманда... ике җаду пәйда булып, аларның йаwызлықларындан халық гаҗиз булғанлар иде, wә аларның фитнәсендән қотылмақда чарасыз қалғанлар иде [Насыйри, 1974, б. 213].

*-ган иде* һәм *-мыш иде* формалары К. Насыйриның сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә сан ягыннан бертигез дәрәҗәдә диярлек һәм һәр икесе дә, нигездә, ике төрле позициядә кулланыла, билгеле бер эш-хәлдән соң башкарылган, тулысынча тәмамланган, күрелеп үткән эш-хәлне белдерә. Мисалларда тагын бер үзәнчәлек күзәтелә: бер төрле үк штамп җөмләләрдә төрле формадагы фигыльләр кулланыла. Мәсәлән, *-ды* кушымчалы фигыльдән соң «мәгәр» сүзе белән башланган җөмләнең хәбәре булып *-ган иде, -мыш иде, -р иде, -ды, -макда иде* формалы фигыльләр килә ала, димәк, алар барысы да бер үк мәгънәне белдерә: ...әфсен уқып селкенде. Мәгәр падишаһның сарайы йанында бер күл бар иде, шул күлгә чумды, ғаиб булды [Насыйри, 1974, б. 214]; ...ишек қақты. Мәгәр мөқаддәм, Әбүғалисина хәлвәфрушның қулыннан тотып, ишектән чығарғач, бу қадәр мең бәла белән хәлвәфрүш Багдадқа төшкән wақыт, ...ул кич төнлә анасына күндермеш иде [Насыйри, 1974, б. 232]; ...мәхкәм тотып торыр иде. Мәгәр Әбүгалисинаның Хадимнәре килеп, қыйссадан хәбәр бирделәр [Насыйри, 1974, б. 245]; ...падишаһына кереп, хәбәр бирде. Мәгәр ул шәһәргә Колония wә падишаһына Дақйанус дийерләр иде [Насыйри, 1974, б. 287] һ.б.

Әлеге мисал-җөмләләрдән аңлашылганча, бер үк типтагы тар контекстта төрле формадагы үткән заман фигыльләренең кулланылуы, аларның реаль мәгънәләреннән бигрәк, тасвирлау-хикәяләү өчен зарур булган вазифаларының актуальлеген күрсәтә дип әйтә алабыз.

К. Насыйриның фәнни хезмәтләрендә аналитик формадагы үткән заман хикәя фигыльләр шактый аз күзәтелә, кулланылган вакытта алар үзләренең парадигматик мәгънәләре белән файдаланыла: «Гөлзар вә чәмәнзар» китабында: ...бу заманға чақлы без, Русийә халқы, ғади халықдан башқаларымыз барчамыз да, мәмлекәтемездә булған үсемлекләрдән дәwалар йасауның хаҗәте йук дип хисапламыш идек. Мин сүземне исбат қылмақ өчен күп дәлилләр китерә алыр идем… [Насыйри, 1975, б. 78]. «Ысулы җәгърәфияи кәбир» китабында: Ибне мулла Ғабденнасыйр әйтәдер ки, мондан мөқатдәм, яғни мең дә сигез йөз җитмеш өченче елда тәҗрибә йөзеннән ғыйльме хисап фәнендә бер китап тасниф итеп басма қалдырмый идем [Насыйри, 1975, б. 84] һ.б.

Әсәрдә бара торган вакыйга-хәлләрне укучыга турыдан-туры мөрәҗәгать итеп, авторның үз исеменнән сөйләнеп хикәяләнә торган сәнгатьле проза әсәрләреңдә дә *-мыш иде* һәм *-ган иде* формалы үткән заман фигыльләре, *-а иде, -адыр иде, -р иде* формалары белән чагыштырганда, нигездә, парадигматик мәгънәләре белән файдаланыла. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә: ...вармақ пәк мөшкел иде: қырда йул бер қарар улмайыб, қар бераз йағмыш иде [Акъегет, 1886, б. 7]; Көнәш нур wә эсселекне чобарланмыш қырларда сачмеш иде [Акъегет, 1886, б. 53]; Бәлки, хәтереңездәдер, ғыйззәтлү укучыларым, Ғайниҗамал абыстай хақында җиденче бабда йазмыш идек [Акъегет, 1886, б. 57].

Әлеге мисалларның барсыңда да *-мыш иде* формалы үткән заман хикәя фигыль үзенең төп-парадигматик, ягъни эш-хәлләрнең тулысынча тәмамланганын, үткәндәге билгеле бер урын-вакыт эчендә башкарылганын, үтәлгәнен сөйләүченең яхшы белүе мәгънәсендә кулланыла.

*-мыш иде* формалы фигыльләр башка мәгърифәтче әдипләрнең әсәрләрендә дә, асылда, шушы мәгънәсе белән файдаланыла, әмма *-ган иде* формасы белән алмаштырылу өстенлек ала башлый. З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында: Бу табылмыш мәктүб рус лисанилә йазылмыш иде. ...Бән исәм ул wақытда Әхмәди Хәмидевнең қызыны алырға мәқсудым йуқ иде, қызны йәрәшмәгән идем. ...Петербургда wақытда Зөләйхайә мәктүб йазған идем. ...Мәктүб бөйлә йазылмыш иде: ...Ахунд хәзрәтләрене күргәч, җәмағател-мөслимен ахунд хәзрәтләренә тәғзыймән йирләреңдән торганлар иде… З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында да бу төрдәге фигыльләрне куллану

шушы ук тәртиптә дәвам итә, *-мыш иде* формасының активрак булуы күренә. Мисаллардан аңлашылганча, З. Бигиевнең бу романында *-мыш иде* формасы эзлекле рәвештә, билгеле бер вакыт эчендә булган, тәмамланган, күрелеп үткән эш-хәлләрне аңлата торган мәгънәсе белән кулланыла. Әдипнең «Мавәраэннәһердә сәяхәт» юлъязмасында *-мыш иде* формасы, нигездә, күптән үткән эшләрне атау өчен дә файдаланыла: Тарихларда мәшһүр әл-Муканғ фетнәсилә мөхарәбәләр 767 сәнәдә ибтида улынып, 15 сәнә қадәр дәwам итмеш иде [Бигиев, 1991, б. 290]. 1863 сәнәдә Мавәраэннәһерә йулланмыш иде [Бигиев, 1991, б. 294] һ.б.

Р. Фәхретдиннең сәнгатьле проза әсәрләрендә *-мыш иде* формасы, нигездә, ике төрле мәгънәсе белән кулланыла: а) үткәннең билгеле бер вакыты эчендә эшләнеп тәмамланган эш-хәлләрне һәм ә) эшләнеп тәмамланган эш-хәлләрнең нәтиҗәсен белдерә, ягъни алда каралып үтелгән мәгънәләре дәвам ителә. «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: ...бән Қазанға килдекем йылда wафат улмыш иде [Фәхретдин, 1899, б. 6]; Қазанға китдекем заманда, Самар–Уфа тимер юлы йаңа эшләнә башланмыш иде [Фәхретдин, 1899, б. 6]; Пароходда исә Сәлимә туташдан гүзәл қызлар wә йахшы кийемле мәхбүбәләр йуқ дәгел иде ләкин һичберенә күңелем дәгел күзем дә төшмәгән иде [Фәхретдин, 1899, б. 36].

Р. Фәхретдиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» романында да *-мыш иде* формасы шушы ук мәгънәләре белән кулланыла: Әсма сигезенче яшенә җитдекендән сабақ уқытмақ заманы тәмам килмеш wә бу фикер Ғаишә абыстай илә Ғаббас мелланың күңелләрендә олуғ бер урын алмыш иде һ.б. Әлеге әсәрдә җөмләләр билгеле бер ритм-көй ясап тезелә, тезелеп киткән бу төрдәге җөмләләрнең хәбәрләре *-мыш иде* формалы фигыль белән тәмамлана: ...хәсрәте әүwәлгедән артмыш иде; ...мәсҗеддән чықартмыш иде; ...күкрәгенә кийереп йатмыш иде һ.б. Бу җөмләләрнең барысында да, нигездә, алдан тәмамланган эш-хәлләрнең нәтиҗәсе бирелә. *-ган иде* формасы сирәк күзәтелә: Без аwылда wақытымызда уқыған идек [Фәхретдин, 1903, б. 41].

Ф. Кәриминең сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә җанлы сөйләмә тел берәмлекләре әдәбиләштерелә. Шулай итеп, «...әдипнең кечкенә күләмле «Салих бабайның өйләнүе» дигән әсәре дә яңа әдәбиятыбыз формалашуы тарихында тирән эчке мәгънәле, зур йөкләмәле, истәлекле күренеш» [Гайнетдинев, 1996, б. 17] булуы белән бергә, татар халкының җанлы сөйләмә телен аның әдәби теле итеп күтәрү ягыннан да әһәмияткә ия булып тора. Бу хикәядә беренче мәртәбә диярлек, башка әдипләрнең хикәяләрендә бик тә сирәк кулланыла торган яңа форма-

лы фигыль кулланыла башлый һәм вакыйганы алып баруда төп көчкә әверелә. Бу – *-а торган иде* формалы фигыль. «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә (1897) җөмләләр эзлекле рәвештә шушы фигыль белән тәмамлана: ...минем күңелемне бик хуш итә торған иде; ...миңа күп хикәятләр сөйли торған иде; ...төшемә кереп саташа торған иде. ...ахырын да бик килештереп хәтем итә торған иде. ...аның йанына бара торған идек [Татар мәгърифәтчелек…, 1979, б. 220–229].

*-а торган иде* формасы, рәттән диярлек болай тезелеп бармаса да, әдипнең башка әсәрләрендә дә кулланыла. «Җиһангир мәхдүм»дә (1898): ...бер-ике бәлеш төбе алып қайта торған иде; ...алтышар-җидешәр иман ижеге ашап бетерә торганнар иде; ...әнкәсе һәм сабақ балалары йәрдәм итә торғаннар иде; ...қат-қат өйрәткәч, хәтерендә қала торған иде [Татар мәгърифәтчелек…, 1979, б. 245]. *-а торган ид*е күрсәткеченең кабатланып, үткән эш-хәлләрне белдерү мәгънәсе белән бер-ике җөмләдә кулланылуы К. Насыйриның «Кырык вәзир» кыйссасында очрый: Йегет әйтде: Ул wақыт мин синең хезмәтеңдә идем, миңа бөтен дөньйа қадәр ингам-ихсан итә торған идең. Һәр ни қадәр Қолтабан дип қычқырсаң да, мин рәнҗеми торған идем [Насыйри, 1975, б. 27]. Башка мәгърифәтчеләр иҗатында әлеге форма бик сирәк чагылыш таба. Ә менә Ф. Кәриминең үткән яшьлекне искә төшерү, анда булган эш-гамәлләрнең кабатлануын күз алдына китерү рәвешендә язылган хикәясендә вакыйганы алып баруда бу форма төп чара булып күтәрелә. Аерым персонаж карашыннан сурәтләнеп язылa торган башка әсәрләрендә инде шактый сирәк кулланыла, яисә «Бер шәкерт илә бер студент» повестындагы кебек (1899) файдаланылмый.

*-а торган иде* формасы классик әдипләрнең беренче әсәрләрендә дә активлашып китә алмый. Г. Исхакыйның «Кәләпүшче кыз» (1900) хикәясендә әлеге күрсәткеч бер мәртәбә кулланыла: Йон йуучылар арасында берсе Камәр булған шикелле, башқалары да қайсы Камәрдән дә күп дөньйа күргән, қайсы Камәр булырға йөри торғаннар иде [Исхакый, 1998, б. 74]. *-а торган иде* формасы әлеге әсәрләрнең барысында да үзенең хәзерге заман сыйфат фигыль вазифасын үтәгән хәлдә еш кабатлана.

Ф. Кәрими әсәрләрендә исә, *-а торган иде* формасы белән рәттән, аңа караганда күбрәк булып *-ган иде* формасы кулланыла: ...Әүwәл дән бераз шәбрәк килгәнгә күрә, атларыбыз тирләгән иде. ...Без бу әрәмәгә килеп җиткәндә, өйлә wақыты булған иде; ...җәннәт кебек бер гүзәл бер җирдә намаз уқып бер истирахәт итсәк, ничек булыр

икән, дип иптәшемә әйткән идем, минем тәклифемне бик хуш күреп қабул итде. ...Хәзергә қадәр Салих бабайның хикәйәтеннән бер дә тат чықмаған иде, ...зуррақ үсеп уқый башлағач, чегәнләр хақында тағын күбрәк нәрсәләр өйрәнгән идек [Татар мәгърифәтчелек…, 1979, б. 220–228] һ.б.

*-ган иде* формасы әдипнең «Җиһангир мәхдүмнең ауыл мәктәбендә укуы» әсәрендә дә рәттән тезелеп бара [Татар мәгърифәтчелек…, 1979, б. 230–245] һ.б.

Ф. Кәриминең кайбер әсәрләрендә *-ган иде* формасы үзенең традицион *-мыш иде* пары белән дә чиратлаштырыла. «Нуретдин хәлфә»дә: Ғайнетдинев үткән йыл монда қымыз эчәргә хатыны, қызы wә ике уғлындан ғыйбарәт булған бөтен җәмәғате илә килгән иде. ...бу қызның исеме Фатыйма wә төсе-буйы бәк чибәр булып, йәшенең унҗидедә икәнлеген дә үгрәнмеш иде [Кәрими, 1996, б. 57]. Ф. Кәриминең әлеге әсәрендә *-ган иде* формасы, ә «Морза кызы Фатыйма» әсәрендә *-мыш ид*е формасы ешрак кулланыла: Бер wақыт, ...Мостафа үзенең бақчасындан йегерме биш верст җирдә булған бер шәһәргә китмеш иде. ...Бичара Мостафа яғмырдан мөхафәзә өчен зонтик қорған иде [Кәрими, 1996, б. 88-89] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, Ф. Кәриминең сәнгатьле проза әсәрләрендә *-ган иде* формасы активлаша, төрле әсәренең темасына бәйле рәвештә, төрле дәрәҗәдә, үзенең традицион пары булган *-мыш иде* формасы белән чиратлашып кулланыла, әлеге формалар төрле мәгънәләре белән реальләшә.

Г. Исхакыйның беренче хикәяләрендә вакыйганы алып баруда *-ган иде* формасы төп чараларның берсе булып кулланыла башлый, *-мыш иде* формасы күзәтелми кебек.

Г. Ибраһимовның беренче хикәяләрендә *-ган иде* формасы активлашса да, *-мыш иде* формасының кулланылышы да дәвам итә. «Гыйшык корбаннары» әсәрендә: Ғыйлем wә мәғрифәтле, тәрбияле ғаиләэчендә дөньйаға килмеш иде. Аны йәштән үк тә йахшы тәрбийәләгәнләр, уқытқанлар иде [Ибраһимов, 1974, б. 447]. Сәғыйд Ғалимәнең күңелендә бик шәрифле урын алмыш иде. ...Ғалимәнең башы күккә тигән иде [Ибраһимов, 1974, б. 452] һ.б.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар прозасында кулланыла торган аналитик үткән заман хикәя фигыльләр хакында сүз алып барганда, *-ачак иде* формасы хакында да фикер әйтү сорала.

Татар халкының җанлы сөйләменә хас булган формаларны тикшерүгә багышланган Г. Фәезханов, К. Насыйри, М. Өметбаевның

грамматика китапларында *-ачак* һәм *-ачак иде* формалары искә алынмый. Әлеге форма Г. Нугайбәкнең «Төрлек» хезмәтендә «киләсе белемсез чакны үткәнгә күчерү» дигән аңлатма белән, «язасы (язачак, язмакчы) иде» рәвешендә күрсәтелеп үтелә [Хангилдин, 1954, б. 205]. Аннан соң төрле галимдә төрлечә фикер әйтелә [Тумашева, 1986, б. 11–22].

Гомумтюркологик планда язылган хезмәтләрдә «-чак эди үзенең кулланылышы һәм бигрәк тә эчтәлеге белән шартлы теләкне белдерә торган *-р иде* формасының заман дублеты» дип санала [Юлдашев, 1965, б. 263].

Татар диалектларында фигыль формаларын өйрәнүчеләр әлеге форманың үткән заман хикәя фигыль һәм шартлы теләкне белдерә торган күрсәткеч дип тикшерәләр [Юсупов, 1986, с. 180–181, 263; 2004, с. 452–453].

Хәзерге татар әдәби телендә дә *-ачак иде* формасының ике вазифа үти алу мөмкинлеге күрсәтелә: а) киләчәк-үткән заман хикәя фигыль һәм ә) шартлы теләкне белдерә ала торган вазифалары [Татар грамматикасы, 2002, б. 137, 165].

XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган текстларда *-ачак иде* формасыннан алда *-ачак* формасының кулланылуы күзәтелә. Әлеге форма сыйфат фигыль, хәл фигыль, киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәләре белән файдаланыла. *-ачак иде* формасы З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында кулланыла башлый һәм ул монда категорик киләчәк заман мәгънәсен аңалата: Муса әфәнде, сүрәи йасинны тәмам иткәч тизмү кәлерләр икән дәйү, сәғатькә қарады. Сәғатьдә йәнә ун дәқыйқадән соңра, тәмам унбер сәғать улачақ иде [Бигиев, 1991, б. 231]. Нәкъ шушы типтагы җөмләдә *-ачак* формасы да кулланыла: Господин Шубин: «Бик йахшы», – дип сәғатькә қарады, сәғатьде йәнә унбиш дәқыйқадән соңра, тәмам бер сәғать улачақ [Бигиев, 1991, б. 234]. Димәк, *-ачак* һәм *-ачак иде* формалары бер үк мәгънәдә була.

*-ачак иде* формасы Р. Фәхретдин иҗатында активлаша. «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1898) әсәрендә: Ләкин бу нәрсәләрнең ахирәттә йәки дөньйада бәнем өчен бер файдасы улачақ идеме йәки йуқмы иде. ...Атамдан қалған байлық бәнем бер йалғызыма йитешәчәк иде [Татар мәгърифәтчелек…, 1979, б. 269] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, *-ачак иде* формасы, нигездә, *-ачак* кушымчасы белдерә торган мәгънәдә, ягъни киләчәктә катгый булачак эш-хәлләрне аңлата, ә *иде* ярдәмлеге *-ачак* күрсәткеченең әлеге мәгънәсен үткәнгә күчерә һәм,

бер үк вакытта, хикәяләү-тасвирлауны алып бара торган үзенчәлекле чара буларак та кулланыла кебек тәэсир ясый.

Р. Фәхретдиннең әлеге әсәрендә *-ачак иде* тагын шартлы теләкне аңлата торган мәгънәсе белән дә шактый еш кулланыла һәм аның бу мәгънәсе «Әсма, яки Гамәл вә җәза» романында да дәвам итеЛә: Ғаишә абыстай әгәр дә дәүләтле кемсә қызы улса иде, Ғаббас меллаға дәгел, бәлки аның хәлфәләренә йар улачақ иде [Татар мәгърифәтчелек…, 1979, б. 313] һ.б.

*-ачак иде* формасы үзенең киләчәк-үткән заман хикәя фигыль һәм шартлы теләкне белдерә торган мәгънәләре белән Г. Исхакыйның кайбер әсәрләрендә дә урын ала. «Кәләпүшче кыз» хикәясендә (1900): Йәтимә қыз Камәр дә туры уқ эшләрен Wафаға тапшырасы булғанға, Wафа аңарға да, билгеле, башқа хатыннарға қылған эшен эшләйәчәк иде [Исхакый, 1998, б. 57]. Мисаллардан аңлашылганча, *-ачак иде* формасы үзенең шартлы теләк мәгънәсе белән ешрак кабатлана, абсолют җөмләләрдә файдаланылганда, әлеге форма, үзенең нигезе *-ачак* кебек үк, киләчәктә тәгаен булачак эш-хәлләрне аңлата: Аныңча, Wафа берлә рәхәтләнеп бөтен ғомерләрен бергә уздырачақлар иде [Исхакый, 1998, б. 65]. Бу типтагы җөмлә әдипнең башка әсәрләрендә сирәк күзәтелә. «Очрашу яки Гөлгыйзар»да: Мондый хатынны тапқанчы эзләйәчәк идем, аннан ары өйләнәчәк идем [Исхакый, 1998, б. 81]. «Зинданда»: 1906 нчы елны 29 октябрьдә университетта қарагруһлардан бер студентның рефераты (бер нәрсә хақында үзенең фикерен сөйләwе) булачақ иде (1998, б. 273). «Бай угылы»нда: ...бердәнбер кызының утыз биш-кырык йәшьтә тол қалуыны күрүе бик аwыр булачақ иде [Исхакый, 1998, б. 151]. Шулай итеп, киләчәктә булачак эшләрнең үткәндәге билгеле бер вакытка бәйле булып үтүе аңлашыла.

Г. Ибраһимовның беренче хикәяләреңдә *-ачак иде* формасының киләчәк-үткән заман хикәя фигыле вазифасында кулланылуы күзәтелми. Ф. Әмирханның беренче әсәрләрендә дә *-ачак иде* формасы, хәзерге татар теленең әдәби нормасы дип аңлатыла торган, киләчәктә булачак эшнең үткәнгә күчерелүе, ягъни үткәннең билгеле бер мизгеленә мөнәсәбәтле рәвештә булачак эш-хәлләрне белдерә торган мәгънәсе белән [Тумашева, 1986, б. 59] кулланыла. «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә: ...концертның икенче фасылы да башланды. Бу фасылда программа буйынча тәклидләр дә булачақ иде. ...бер татар скрипач уз таснифы «Қайғы» исемле көйне уйнайачақ иде [Әмирхан,

1984, б. 13]. «Бәйрәмнәр»дә: Wәли абзый иртәгә, түләп алырға кирәк булғач, уғылының әдәбийатта танцевать итмәгән һәм «урыс» түгел икәнен катған беләчәк иде [Әмирхан, 1984, б. 27]. «Хакарәт саналган мәхәббәт»тә: Аның бөтен ғомерендә бу бер генә қуанып қарарлық нәрсәм дип мөқатдәс күреп сақлаған нәрсәсе дә бу көннән башлап, салқын тимер шикелле, йөрәгенә туңдырып торырға ғына йарайачақ иде [Әмирхан, 1986, б. 31]. Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, *-ачак иде* формалы җөмләләр һәр әсәрнең фәкать үзенә генә кирәк булган ритм-көен барлыкка китерә торган рәвештә төзелә.

М. Гафури иҗатында *-ачак иде* формасы сирәк күренеш. «Үги балалар»да: Мәдрәсәдә тәхсил иткән ғыйлемләрдә бик мәғлүм wә ғади булғанға күрә, аларны онытып зарар итәчәк дәгел иде [Гафури, 1983, б. 35]. ....Бу поезд, монда күп тормай, Самар тарафына китәчәк, Ғали хәзрәт ул тарафта шифаханәдә (больниста) тәмам төзәлеп беткәч кенә асыл wатанына қайтачақ иде [Гафури, 1983, б. 62] һ.б.

Әлеге әдипләрнең иҗатында һәм шулай ук Ш. Камал әсәрләрендә дә *-ачак иде* формасының шартлы теләкне белдерү мәгънәсе белән ешрак файдаланылуы күзәтелә.

Шулай итеп, тикшерүләр күрсәткәнчә, XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган текстларда, аеруча сәнгатьле проза әсәрләрендә, *-р иде (ирде), -а (дыр) иде, -макда иде, -мыш иде, -ган иде, -а торган иде, -ачак иде* кушымчалы үткән заман хикәя фигыльләрнең вакыйганы хикәяләүдә төп чара буларак файдаланылуы һәм эзлекле кулланылуы аңлашыла.

Болар белән бергә хикәяләүне алып баруда *-мак иде, -уда иде, -учан иде, -ып иде* формалы үткән заман формаларының да файдаланылуы күренә. Төрле әдип әлеге формаларны төрле ешлыкта кабатлый, төрле дәрәҗәдә файдалана.

*-макда иде* формасы белән бергә, мәгънәләре белән аңа якын булган *-мак (лык) иде* һәм *-уда иде* формалы үткән заман хикәя фигыльләр дә күзәтелә. К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы» нда: Безнең морадымыз сезгә, икенче җәһәтдән, зәхмәтсез wә мәшәқатьсез башқа бер һөнәр wә санағать үгрәтмәк иде [Насыйри, 1974, б. 229]; Һи ахмақ, безне үз рәимезгә қуймадың. Өйдә wақытда қанын алмақ идек [Насыйри, 1974, б. 259] һ.б. З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында: Җәзасы бу иде Муса Салиховқа ун сәнә каторжный работада хезмәт итмәклек иде [Бигиев, 1991, б. 240]; ...Ғабденнәсыр әфәнденең ғаразы Муса әфәндийе қәтелдә мәғйүб итдереп, Әхмәди

байның кызыны йөз мең рублә ақча илән кәләшлеккә алмақлық иде [Бигиев, 1991, б. 241] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә: Ләкин сәүдәгәрләр базарыннан қайтып килдекләре хәлдә, бу Дарвин мәймүнләре қайдан килеп, қайда бармақлар иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 331]. «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: ...wә башымны алып бер тарафқа китәргә қарар вирдем. Төркийә, Мисыр мәмләкәтләренә йөрмәк, Қытай wә Йапон өлкәләрене күрмәк, Һиндстан wә Җава туфракларыны зыйәрәт итмәк уладыр идем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268] һ.б.

Ф. Кәриминең «Бер шәкерт илә бер студент» (1899) хикәясендә: Хәзрәт берлән күрешүдән минем мақсудым дөньйа wә ахирәт өчен аннан файдалы сүзләр ишетмәк wә татлы бер мосахәбәт итмәк иде [Кәрими, 1996, б. 37]. «Нуретдин хәлфә»дә: Аның фикере: Ғайнетдиневләр бу сәнә дәхи монда килгәч, анлар илә гүзәлчә танышып, үзенең Камаләт wә фазыйләтләрен аңлатмақ, wә йаwаш-йаwаш анлар илә мөнәсәбәттә булынып, үзен анларға сөйдермәк, әгәр мөмкин булса, Ғайнетдиневкә ысул җәдидәнең йаманлығын аңлатып, аның фикерен иске ысулға дүндермәк иде [Кәрими, 1996, б. 65]. «Морза кызы Фатыйма»да: Истамбулға чықмақ өчен иң йақын йул Севастополь арқылы китмәк иде [Кәрими, 1996, б. 113] һ.б.

Ф. Кәрими иҗатында *-мак иде* формасы *-уда иде* формасы белән чиратлаша башлый. Мәсәлән, «Җиһангир мәхдүм»дә: Әхмәтша хәзрәтнең нийәте мәдрәсә тотып, дәрес әйтүдә иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 230]. ...Җиһангир мәхдүм генә әүwәлгесе кебек тырышуда иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 245] һ.б.

*-уда иде* формасы Г. Исхакый иҗатында активлаша, күп кенә әсәрләрендә вакыйганы алып баруда сизелерлек чара булып күтәрелә. Мәсәлән, «Кәләпүшче кыз» хикәясендә: Кәримә бала җанлылығы йомшақ күңеллелеге илә, ...ике бөртек ғазиз балаларын тәрбийәгә ғомерен сарыф қылмақчы булса да, бердән дәүләте юқлығы, икенчедән, 32–33 тән үтмәгән йәшьлеге, гүзәллеге бу уйына йул бирмәүдә иде, Кәримә балаларын бик йақын күргән шикелле, балалары да... ата мәхәббәтен дә аналарына биреп сөюдә иделәр [Исхакый, 1998, б. 52].

*-уда иде* формасы әдипнең башка әсәрләрендә файдаланыла һәм, мисаллардан аңлашылганча, әлеге күрсәткеч үзенең темпораль мәгънәсе белән бергә, сурәтләнә торган хәлләргә карата авторның теләктәштә булуын яисә кызгануын, яки шатлануын, гомумән, хуплавын

белдерә торган мәгънәләр дә аңлата. *-уда иде* формасы башка әдипләр иҗатында күзәтелми булса кирәк.

*-учан иде* формасы да бер мәртәбә Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә файдаланыла: Бу вақыйға исә ыславан халқының бу мәмләкәткә кәлмәзләрендән мөқаддәм (элек) уладыр. Болғар халқы һөнәрчән wә сәүдә идүчән иде. Бу көндә Қазан исламларында улған сәүдәгәрлек кәсебе, бабалары улған болғарлылардан мирасдыр [Фәхретдин, 1899, б. 30]. Әлеге форма Г. Исхакыйда да күренеп китә: Шәрәфи хаҗи бик хурланучан иде [Исхакый, 1991, б. 301].

*-учан* кушымчасының *бул* ярдәмлеге белән килеп, хәзерге татар әдәби телендәге *-а торган була* мәгънәсендә килүе, К. Насыйриның «Фәвакиһелҗөләса» китабында күренә: Күп қайнар ашап, қайнар эчергә ғадәтләнгән кеше һәрқайчан қурқучан буладыр. Wә һәм күп арақы wә ғайре эчемлекләр эчкән кешенең йөрәге зәғыйфь буладыр, қурқучан буладыр [Насыйри, 1975, б. 253]. Шул үк форма Ф. Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә файдаланыла: Қартларның барысы да болай булмый бит, бәғзыларының табиғатьләре бозылыбрақ, холықлары тарайып китә wә тиз ачуланучан буладыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 220]. Әлеге форма шул ук мәгънәсе белән Г. Исхакыйда да күзәтелә: Бәйрәм алдында, атына утырып, базарға барып, әллә ниқадәр бүләк-салак алып қайтучан булды [Исхакый, 1991, б. 291].

*-ды иде* күрсәткечле хикәя фигыль кебек, *-учан иде* формасы да Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә бер мәртәбә файдаланыла булса кирәк: ...Сәлимә туташның тыныч урынға ихтияҗы варлығыны ачық белдем иде. Буңа мәрхәмәт итмәкне инсанлығым җәһәтендән үземә бер лязем эш дийә хисаб итдем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 275]. Контексттан аңлашылганча, *-ды иде* формасы *-ганга, -гач* формалы хәл фигыльләрнең мәгънәсе белән кулланыла.

Сирәк файдаланыла торган формалардан тагын *-ып иде* күрсәткечен әйтеп үтергә кирәк. Бу форма Ә. Уразаев-Кормаши кыйссаларында күзәтелә. «Таһир илә Зөһрә»дә: Мин бер қолың бу хәлне күреб идем, / Чәнчәен дип ғайрәтемә килеб идем... [Татар әдәбияты, 1957, б. 315].

Мисалдан аңлашылганча, *-ып иде* формасы сөйләүче күз алдында яңа гына булган хәлне белдерә. Әлеге мәгънә бу форманын төп мәгънәсе булып санала [Юлдашев, 1965, б. 192–193].

*Кыскача нәтиҗәләр.* XIX гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән әдәби әсәрләрдә аналитик үткән заман: *-р/-маз иде (ирде), -йур иде, -а (дыр) иде, -мыш иде, -ган иде, -макда иде, -а торган иде, -ачак иде, -мак (-лык) иде, -учан иде, -ып иде, -ды иде, -уда иде* формалары белән кулланылышта була. Өйрәнелә торган язма текстларда аналитик үткән заманнарның хәзерге әдәби телгә хас булганнарының да, җанлы сөйләшләрдә файдаланыла торган һәм шулай ук язма традициянең дәвамы буларак килә торган формаларның да төрле әсәрдә төрле дәрәҗәдә кулланылуы күзәтелә: *-р/-маз (мас) иде, -а (дыр) иде* күрсәткечләре сәнгатьле проза әсәрләрендә вакыйга-хәлләрне алып баруда актив чара булып тора, *-а иде* һәм *-а (дыр)* формалары язма текстларда, диалектлардан аермалы буларак, мәгънә ягыннан аерымланмыйча кулланыла, *-дыр* кушымчасы традициянең дәвам итүен чагылдыру вазифасын үти.

*-ган иде, -мыш иде, -макда иде, -ачак иде, -а торган иде* формалары да шактый актив кулланыла.

*-мак (-лык) иде, -уда иде, -учан иде -ып иде, -ды иде* формалары сирәк файдаланыла.

*Иде* ярдәмлеге, сөйләү моментында актуаль булган эш-хәлләрне белдерә торган *-а (дыр), -р/-маз (мас), -йур, -макда, -мак, -учан, -уда* һәм сөйләү моментында эшнең нәтиҗәсен белдерә торган *-ган, -мыш, -ып* кушымчаларының мәгънәсен үткәнгә күчерү белән бергә, сәнгатьле проза әсәрләрендә хикәяләүне алып бару, башка тасвирларга фон бирү вазифасын да үти. Шуңа күрә *иде* ярдәмлеге белән ясалган аналитик формалар матур әдәбият стиленең тезмә һәм драма жанрларында һәм публицистика белән фәнни әдәбият стилендә язылган текстларда, сәнгатьле чәчмә әсәрләрдәге кебек, рәттән эзлекле булып тезелеп бармый.

*-ган иде, -мыш иде, -ып иде* формаларында, башка аналитик формаларга караганда, функциональ-стилистик вариантлылыкны барлыкка китерү һәм аерымлауда көчлерәк чагыла: *-мыш иде* үз чоры татар әдәби теленең җәдиди госманлы варианты белән язылган текстларда, *-ган иде* – халыклашкан варианты белән язылган текстларда ешрак кабатлана һәм алга таба кулланылышын саклый.

Бер үк форма төрле әдипләрнең иҗатында да, бер үк әдипнең төрле әсәрләрендә дә төрле дәрәҗәдә кулланыла, *-ачак иде* формасы Ф. Әмирхан әсәрләрендә шактый актив, ә Г. Ибраһимовның беренче хикәяләрендә бөтенләй диярлек файдаланылмый, шул ук форма Г. Ис-

хакыйның «Зиндан» повестенда эзлекле булып бара, башка әсәрләрендә сирәк күзәтелә.

Күпсанлы мисалларны анализлаудан аңлашылганча, аналитик үткән заман хикәя фигыльләрнең унөч формада актив хәрәкәтә булуы, хәзерге вакыттагы өч заман булып кына кулланылуы белән чагыштырганда, авторларга сайлап файдалану өчен байлык, киң җирлек булып санала.

Шулай итеп, XIX гасыр – XX йөз башына кадәр иҗат итеlә торган әсәрләрдә үткән заман хикәя фигыльләрнең синтетик һәм аналитик төрләренә, кыпчак һәм угыз телләренә хас булган нормаларда кулланылуына, авторның нинди максатны күздә тотып иҗат итүенә бәйле рәвештә түбәндәге норма вариантлары хасил булуы күзәтелә:

1) графо-орфографияга нигезләнгәне: а) I и II зат кушымчалары алганда, *-ды* аффиксы сузыклы һәм сузыксыз булып, ә) *-ган* морфемасындагы (г) графемасының калынлыкта – غان, нечкәлектә – كن, аерымланып һәм саңгырау тартыгы белән чиратлашып – قان , *-ачак* кушымчасында (ч) һәм (җ) тартыкларының алмашынып язылуы;

2) морфологиягә нигезләнгәне: а) үткән заман хикәя фигыльләрнең төрле күрсәткечләр белән белдерелеп, төп парадигматик мәгънәсендә кулланылуы, ә) сөйләм эчендә өстәмә төсмерләр белдереп (киңәйтелү, кабатлану) синтагматик вазифасын үти алуы, б) үткән заман хикәя фигыльләрнең күчерелмә мәгънәдә кулланылуы, в) башка наклонение төрләренең үткән заман мәгънәсендә килә алулары;

3) синтаксиска нигезләнгәне: *-р иде, -мыш иде, -йур иде* формаларында *иде* ярдәмлегенен кушылып *(-рды, -мышды, -йурды)* языла алуы. Үткән заман мәгънәсенең лексик чаралар белән дә көчәйтелүе.

XIX гасыр – XX йөз башы татар әдәби телендәге үткән заман хикәя фигыльнең парадигмасын барлыкка китерә торган шушы хәзинәдән язма текстның яки стиле, яисә шул стильнең нинди дә булса бер жанр-төренең таләбе белән кайсы да булса бер чараның махсус рәвештә сайланып алынып, ешрак кулланылуы әлеге категориянең функциональ-стилистик вариантлылыгын барлыкка китерә.

Хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыль өйрәнелә торган чорда *-а (дыр), -р, -йур, -маз, -мас, -макда (дыр), -ачак (дыр), -айды, -ады, -гай, -ганди, -гани, -уда, -учан, -асы* формаларында чагылыш таба.

Хәзерге татар теленең үсеш-үзгәрешенә нисбәтән караган вакытта, *-а (-ә, -ый, -и)* хәзерге заман хикәя фигыльнең, *-р (-ар, -әр, -ыр, -ер)* барлыктагы, *-мас, -мәс* юклыктагы билгесез киләчәк заманның,

*-ачак, -әчәк* категорик киләчәк заманның әдәби норма күрсәткечләре [Татар грамматикасы, 2002, б. 122–124, 135–138], *-гай* формасы әдәби телдә дә, диалектларда да теләк фигыльнең юклыгында [Татар грамматикасы, 2002, б. 155; Юсупов, 2004, с. 482], *-ады (-ади, -аты)* һәм *-га (-гали, -гани)* кушымчаларының себер татарлары сөйләшләрендә, *-учан, -уда* кушымчаларының урта диалект сөйләшләрендә [Юсупов, 2004, с. 324–326], *-р, -йур, -рды* формаларының, гомумтөрки язма традициянең дәвамы буларак [СИГТЯ, 1988, с. 371, 406–407], угыз төркеме телләрендә хәзерге заман хикәя фигыль булып кулланылулары, *-макда (дыр)* формасының да шундый ук вазифа үтәве мәгълүм [Юлдашев, 1965, б.153].

XIX гасыр ахыры – XX йөз башында иҗат ителгән төрле стиль һәм жанр-төрдәге язма текстларда әлеге заман күрсәткечләре төрле дәрәҗәдә (актив-пассив) һәм төрле ешлыкта кабатланып кулланыла, әмма аларның барысы да үз чоры әдәби теленең нормасы булып санала.

Татар теле белемендә *хәзерге-киләчәк* дигән терминның мәгънәсе тәгаенләнгән. Л. Җәләй үзенең хезмәтендә *-р* һәм *-а* кушымчалы фигыльләрнең хәзерге заманны да, киләчәк заманны да белдерүләрен язма истәлекләрдән алынган мисаллар белән аңлата һәм нәтиҗә ясый: «...килә (ул) һәм килер (ул) формаларын янәшә һәм бер-берсе функциясендә йөртү татар теле тарихында ерактан ук килә һәм озак вакытлар дәвам итә. ...«Хәзерге-киләчәк заман» формасының *(-ыр, -ер, -р)* ике мәгънәдә: һәм киләчәк, һәм хәзерге заман мәгънәсендә йөргәне кебек үк, хәзерге заман формасы *(-а, -ә, -ый, -и)* да киләчәк заман мәгънәсендә кулланыла икән» [Җәләй, 2000, б. 212–219]. Дөрес, әлеге фикернең, интуитив-гомумирәк булып беренче татар грамматикаларында ук чагылыш табуы күзәтелә. Борынгы төрки чорда ук күп төрле функциональ мөмкинлеге белән кулланылышта булган *-р* формасына [СИГТЯ, 1988, с. 890] татар телен фән буларак өйрәнеп язылган беренче татар грамматикаларында да игътибар ителә. Г. Фәезханов *-р* формалы фигыльнең хәзерге һәм киләчәк заманның мәгънәсен белдерүенә игътибар итә, әлеге фигыльнең берлек һәм күплек саннардагы төрләнеш үрнәген бирә, I зат берлек санда кыска кушымча *-м* (م), күплектә *-без* (بز) кушымчасының кушылуын искәртә [Фәизхан, 1887, б. 22]. К. Насыйриның «Әнмүзәҗ» хезмәтендә (1895) *-а* кушымчалы фигыль хәзерге заман (халь) *-р* күрсәткечле фигыль мозарыйг-киләчәк заман дип атала, төрләнеш үрнәгендә I зат берлек санда тулы *-мән (-мен)* (من-), күплектә *-мыз* (مز-) кушымчалары күрсәтелә [Насыйри, 1975, б. 73].

Бу хезмәтләрдә *-р/-мас* кушымчалы заман төрки телләрнең иң борынгы заман формаларыннан санала дип белдерелә. Иске татар телендә язылган истәлекләрдә әлеге форма традицияне дәвам итәрәк кулланыла. Без өйрәнә торган чорда иҗат ителгән әдәбиятта да *-а* һәм *-р* кушымчалы фигыльләрнең хәзерге һәм киләчәк мәгънәне белдереп файдаланылулары күренә.

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-бистәви әс-Сәгыйди» (1845, 1889) әсәрендә *-р, -а* формалы хәзерге-киләчәк заман фигыльләре файдаланыла, борынгы татар әдәбиятының башка әсәрләрендәге традиция дәвам ителә: Бер көнне хуҗа Хәсән Бәсри мәгәр / Хәзрәти Рәбиға Гөдәвине күрәр, ...Вирде ул шәһхә җавабы ба саwаб / Беләсән ...байғ идеб базарә иблек, ошбу хин, ...қыйлдым боны кем белерсән [Каргалый, 1889, б. 2]. Мисаллардан аңлашылганча, III зат берлек – كورار (күрәр), II зат берлектәге – بيله سن (беләсән), بلورسن (белүрсән) фигыльләре, персонажларның үзара сөйләшүе бирелә торган өзектә хәзерге заман мәгънәсе белән кулланыла. Шул ук мәгънәдә *-р, -йур, -ә* кушымчалы фигыльләр чиратлаша: Деләйүр андин дәхи Алла өчүн / Һәм Халиулла ишедер аны чөн... / дүзәтер филхаль дәхи бер қапуны / Ул қапудан килә һәм әһле ғадә... [Каргалый, 1889, б. 3], әмма бу юллардагы *ишедер*, *дүзәтер* фигыльләре киләчәк заманны белдерә. I зат күплектәге барлык һәм юклыктагы – *сәүүрез* киләчәк заманны белдерү мәгънәсе белән кулланыла: Нәчә күрә күземез дидарене / Җан-у-деллә сәүүрез әғйарыны, /...Улимазыз аңа дәхи дәстгир [Каргалый, 1889, б. 3]. I зат күплекнең юклыктагы *-а,* барлыктагы *-р* кушымчалы формалары хәзерге заман мәгънәсе белән кулланыла: ...әйләмәз асла болар сабыр-у-пәзир..., йиәрмез хәр мисал [Каргалый, 1889, б. 4] һ.б.

II зат берлектәге *-әсен* кушымчалы фигыль эшкә кушу мәгънәсен белдерә: ...мәшғуль итәсән, ...сүндерәсән [Каргалый, 1889, б. 4], ...тәүбә итәсез ба сар [Каргалый, 1889, б. 9] һ.б.

III зат күплек сандагы *-а* кушымчалы фигыль киләчәк заманны белдерә: Мөшәwәрәт қыйлдылар бу эшдә фөҗар / Варалар малы wафирлә зәнинә / Вирәләр би қыйас аңа хәзинә, ...бағлаталар аны (Фикер иттеләр: барырлар уйнашчы хатынга, бирерләр чагыштыргысыз күп хәзинә, ...бәйләтерләр аны)... [Каргалый, 1889, б. 5] һ.б. Суфи Аллаһиярның сүзләре китерелгәч, аның китабы турында болай диелә: Дидеке мәшһүрдер, һәркем белер / Һәм китабы җөмлә илләрдә йөрер [Каргалый, 1889, б. 11]. Бу җөмләдәге *-р* кушымчалы фигыльләр хәзерге

заманның гадәти эш-хәлләрне белдерә торган синтагматик мәгънәсе белән кулланыла.

Киләчәк заман *-ачак* кушымчасы белән дә күрсәтелә: Мондыйн отры улачақ билә ғыйтаб (Моннан да артык булачак азарлау) [Каргалый, 1889, б. 3]; Ишедәчәк ул нәби Хақдан моны [Каргалый, 1889, б. 8]; Күричәк ошбу бәлайы әғзами... [Каргалый, 1889, б. 9] һ.б. Шулай итеп, Ә. Каргалый үзенең әсәрендә *-р* һәм *-а* формаларын, язма традициянең дәвамы буларак, хәзерге һәм киләчәк заманнарны белдерү өчен файдалана, сөйләү моментына туры килү-килмәү мәсьәләсе сүз җаеннан аңлашыла, *-йур* күрсәткечле фигыль белән чиратлаштыра; *-мыш* кушымчалы исем фигыльнең I зат берлек саны да гадәти хәзерге-киләчәк заман мәгънәсендә кулланыла: Сим-у дөрр ирмәс, әлемдә – ике пул / Биләсән, йа сөруре әһле қабул: / Баиғ идеб базарә иблек, ошбу хин / Алмышем (المشم), белгел, һиммәм-әл мөэминин / Қулымда ике ақча, беләсең, бу wақытта базарда җеп сатып, ақча аламын, белгел [Каргалый, 1889, б. 3].

Г. Кандалый шигырьләренең күбесендә, турыдан-туры хискичерешләр белдерелә. I заттан язылганга күрә, бу шагыйрьнең иҗатында хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльләре эзлекле рәвештә кулланыла.

*-р* кушымчалы фигыль, хәзерге телдә *-а* күрсәткечле фигыльнең:

1) еш кабатлана торган гадәти эш-хәлләрне белдерә торган синтагматик мәгънәсе белән файдаланыла: ...Әгәр ачлар (чәй) эчәр булса, / Белерсән: барчасы туқдыр [Кандалый, 1988, б. 84]; ...Йоқыны мөндәфиғ әйләр / Белер моны мөҗәррибләр [Кандалый, 1988, б. 84]; Сурәтең дөшемә керер / Дөшем эчрә күзем күрер / Күз алдымда биеп йөрер... [Кандалый, 1988, б. 148];

2) тормышта гомум кабул ителгән, хакыйкать булып саналган вакытка мөнәсәбәтсез эш-хәлләрне белдерә: Надан кеше көтү көтәр / Ғалим кеше Бохар китәр... / Бәнем ғомрем шулай үтәр [Кандалый, 1988, б. 79]; Бу тәқдир дигәнең нидер? / Изеп, йәнчеп, орыр йиргә / ...Кеше дигәнең дә мәзълумдыр: йөгерер, йығылыр, торыр / Башыны ташларға орыр / Сөренмим дип әҗәлләргә [Кандалый, 1988, б. 92] һ.б.

*-адыр* кушымчалы фигыльләр дә шул ук мәгънәдә кулланыла: Моңайып сайрыйдыр қошлар... / Моңайыладыр безгә дә / Мөбарәк айлар тулғанда / ...Күңелдә қалмыйдыр ғилләт / ...Қаты ташдай йөрәкләрне / Бу май айы эретәдер [Кандалый, 1988, б. 80]; ...Диwанаға

әйләнәдер ғазиз башлар / Күземдин ағадыр қанлы йәшьләр [Кандалый, 1988, б. 110].

*-а* кушымчалы фигыльләр дә шул ук мәгънәдә файдаланыла: Үсеп бара ла бер җаный / Чықып бара матур даный / ...Үзе йаңа үсеп бара / Йөзе мисле маһа пара (айга пар) [Кандалый, 1988, б. 138], ...Күземдин қанлы йәш аға / Хәсрәтеңдин, әйа җаным / ...Йәшләр түгел – қан йылаймын / Сәне сағынған чағымда... [Кандалый, 1988, б. 146] һ.б.

*-а* кушымчалы фигыль киләчәк заман мәгънәсе белән дә кулланыла: Җөмлә гөлнең нуры китә / Сачәк wақытлары үткәч / Матур қызның қадре китә / Йегерме йәшенә йеткәч... Бу мәгънәдә дә *-а* һәм *-р* кушымчалы фигыльләр чиратлаша: Җиһан бағлары ки нурлана / Җөмлә гөлләр сачак атқач / Бәнем күңлем тынычланыр / Синең қуйын ғынаңа йатқач [Кандалый, 1988, б. 147]. Шул ук мәгънәдә *-р* формалы фигыль дә кулланыла: Әйа җаным, сәне қайдин табармын? / Мамық берлән ничек утны йанармын?! / Бән бичара сәне қайдин күрәрмен / Чықмыйча утыңызда күп йөрермен... [Кандалый, 1988, б. 156]. Бу фигыльнең юклык формасы да еш кабатлана: Қулым йитмәс, ки тотсам, йар, үзеңне / Күзем йитмәс, ки күрсәм, йар, үзеңне [Кандалый, 1988, б. 156] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, *-р, -а* кушымчалы хәзерге-киләчәк заман фигыльләренең, асылда, дәвамлы, кабатлаулы эш-хәлләрне белдерә алу үзенчәлеге күзәтелә.

XIX гасырның икенче яртысында – XX йөз башында иҗат ителгән тезмә әсәрләрдә *-а* һәм *-р* кушымчалы фигыльләрнең хәзерге һәм киләчәк заманнарны белдереп кулланылуы дәвам ителә. Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1879) әсәренең тезмә өлешендә мондый өзек бар: Ир йегетләр ирлеген қыйлмайынча қуйарма? / Шир йегетләр сүзләрен үлменчә қуйарма? / Ғашыйқ булған йарыннан йегет күңеле сүнәрме? / Күңел қуйған йар булса, үлмәй күңеле сүнәрме? һ.б. [Татар әдәбияты, 1957, б. 304]. Аңлашылганча, *-р* формалы фигыльнең сүз җаеннан юклыктагы *-мас* формасы көтелә торган урынга, сорау рәвешендә барлыгы бирелә һәм хәзер дә, киләчәктә дә булачак эш-хәлләрнең булуы аңлашыла. Тулы кушымчалы II зат берлек сандагы фигыль киләчәк заманны белдереп кулланыла: Арғамаққа менәрсең, күп җирләрне үтәрсең / Ғашыйқ йарың Зөһрәне кемгә куйып китәрсең [Татар әдәбияты, 1957, б. 304]. Аллаһыга ялвару да шундый ук фигыльләр белән белдерелә: Қодрәтең күп, ходайа, һәр ни қыйлсаң қыйлырсән, Ғарипләрнең хәлене син белерсең, ходайа. / Һәр

ни қыйлсаң бәндәңә, син қыйлырсән, ходая, / Мин бичара қолыңа рәхим қыйлсаң, ходайа... [Татар әдәбияты, 1957, б. 309].

*-а* формалы фигыльләр дә даими, кабатлаулы мәгънәсе белән кулланыла: ...Wәзир затқа бирерме, қарап торған бер қызын / Хан задәләр килмиме? Шаһзадәләр килмиме? / Җиде оҗмах хурыдай нур йегетләр килмиме? / Ишеткән җан қолақтан бар да ғыйшық тота, ди / Ғайрәтеңнән қурқып ул серен эчтә тота, ди / Бу қызыңның ғыйшқыннан бары да қан йота, ди... [Татар әдәбияты, 1957, б. 297] һ.б. Димәк, әлеге әсәрдә хәзерге-киләчәк заманның һәр ике формасы да бер үк вазифа үтәп файдаланыла.

Шуның белән бергә, Ә. Уразаев-Кормаши кыйссаларының тезмә өлешендә, хәзерге-киләчәк заманны белдерү өчен, башка авторларда сирәк күзәтелә торган, *-ады/-әде, -айды/-әйде* һәм *-ганди/-канди, -гани* күрсәткечләрен файдалана: ...Сазың күп моң қыйлады, ишеткән таң қалады / Ғариб ғашыйқ йақын кил, исемеңез кем булады [Татар әдәбияты, 1957, б. 308]; ...Патша Багдад китәди, тиз заманда җитәди / Патша қызын сөйгәннең ғазабы бушка китәди [Татар әдәбияты, 1957, б. 327]. Мисаллардан аңлашылганча, ике юллыкның беренчесендә, халык җырларындагы кебек, гомуммәгълүм фикер әйтелә, ягъни *-әди/-айды* формасын, *китә ди*, *аглай ди* дип таркатырга мөмкин кебек, икенчесендә күз алдында булган хәл сурәтләнә, кушымчаны аерып карап булмый, *-а* формалы хәзерге заман белән алмаштырып була: ...қыз исемендә китә, ...хурга охшый һ.б. Юклык формасы да хәзерге заман белән алмаштырыла ала: ...Булғанда без фәкыйрьгә фәрманыңыз / Қалмайды, торып әйтүгә дәрманымыз [Татар әдәбияты, 1957, б. 315], ...Алдырғаным қулыма әле дә булса килмәйди / Килгән адам хәл сорап күңелемдәген белмәйди... [Татар әдәбияты, 1957, б. 327] һ.б.

*-а(й)ды* формалы фигыльнең юклыгы *-масды* күрсәткече белән дә бирелә. «Кыйссаи Бүз йегет»тә: Ғақылсызға сүз әйтсәң, күкрәгенә қунмасды, / Рәхимсезгә сүз әйтсәң, ни қылсаң да булмасды... [Уразаев-Кормаши 1874, б. 21]; Қанатларын киссәң дә, шоңкар қарға булмасды, / Көнгә буйаб китерсәң дә, Зәйтүн кийәү булмасды... [Уразаев-Кормаши 1874, б. 37]. һ.б. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә»дә әлеге мәгънәне бирүдә *-масдыр* формасы кулланыла, транскрипцияләгәндә, [мастыр] яңгырашы ала: Ғыйшқым чигеп күрмәсә, ул қадеремне белмәстер, / Ғашыйқларның сүзене қолағына элмәстер... [Татар әдәбияты, 1957, б. 291], ...Күрсәм, күзем җитмәсдер, әйтсәм, сүзем бетмәстер, / Қайгың истән китмәстер, Зөһрә җаным, әлфирақ [Татар әдәбияты, 1957, б. 305].

«Кыйссаи Таһир илә Зөһрә»нең бер үк икеюллыгында *-гани* һәм *-ганди* формалары чиратлаша: ...Таһир йарың килгәни, тор, жанашым, торсана / Моңлы Таһир килгәндә, уйан, Зөһрә солтаным [Татар әдәбияты, 1957, б. 311]; *-айди* һәм *-ганди* формасы чиратлашып кулланыла: Әмереӊ қылыч сирмәйди, қузый әман теләйди / Қара күзле жан Зөһрәм, қаршы чығып килгәнди... [Татар әдәбияты, 1957, б. 333]; *-канди* формасы кабатланып кулланыла: Күңел зарға батқанди, қайғың жанға батқанди / Таһир жаным, ғашыйқым, нидән күңелең қайтқанди [Татар әдәбияты, 1957, б. 316]. Мисаллардан аңлашылганча, *-ганди* формасы *-ган* кушымчасы белдерә торган эшнең нәтиҗәсен сөйләү моментына күчерә: ...Таһир йарың килгәни, тор, жанашым, торсана / Хәсрәтеңдә зар булған, тумышыннан йар булған / Моңлы Таһир килгәнди, уйан, Зөһрә, солтаным... [Татар әдәбияты, 1957, б. 311]; ...Күңел зарға батқанди, қайғың жанға батқанди / Таһир жаным, ғашыйқым, нидән күңелең қайтқанди [Татар әдәбияты, 1957, б. 316]. Билгеле булганча, «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» текстында әсәрнең чәчмә өлеше тезмә өлешенә «айғаны», «әйткәне», «әйтте», «ғарыз қыйлды», «ғарыз қыйлғаны», «әман теләгәне» кебек формалар белән бәйләнә һәм контексттан чыгып караганда, *-ганы* күрсәткече *-ды* формасы кебек үк вазифа үти булып чыга, ягъни *-ган* кушымчасы белдергән эшнең нәтиҗәсе сөйләү моментында дәвам итеүә, сөйләүче күреп тора булып аңлашыла, димәк *-ганы* формасы үткәндә булган эш-хәлнең нәтиҗәсен (перфектны) башка чаралар кебек, сөйләү моментында да актуаль булган итеп ясый, ягъни (инфектка күчерә) [СИГТЯ, 1988, с. 413–414]. Бу авторның кыйссаларында I һәм II зат берлек-күплектә *-гай/-кай* формалы киләчәк заман фигыле файдаланыла. «Кыйссаи Бүз йегет»тә: ...Әмер қыйлыб Алламыз, терек булсақ, қайтқаймыз / Тере булсам, қайтқанмын, үлсәм, сәлам әйткәймен... [Уразаев-Кормаши 1874, б. 10]; Мәғкүл сүздер, барғаймыз, Хақ йазғанын күргәймез / Без йулында қорбанлық, хезмәт итеп йөргәймез... [Уразаев-Кормаши 1874, б. 59] һ.б. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә»дә: Инде қайчан йөргәймез, сезне кемнән сурғаймыз? / Борынғыдай бер булып, инде қайчан йөргәймез [Татар әдәбияты, 1957, б. 305]; ...Үлсәм инде үлгәймен, Хақ йазғанын күргәймен / Әман бирсәң, бераз көн дәүран сөреп йөргәймен [Татар әдәбияты, 1957, б. 318]. Китерелгән шигъри өзекләрдән аңлашылганча, *-гай* кушымчалы киләчәк заман хикәя фигыльнең берлек һәм күплектәге I заты, нигездә, билгеле берәр шарт үтәлгәндә, яисә инде үтәлгән эшне (хақ язған) тагын бер мәртәбә расларга кирәк

булганда (хақ йазғанын күргәймез) һәм дә ки шул үтәлгән эштән соң булачак эш-гамәлне күзаллаганда (күргәймен, йөргәймен) файдаланыла.

*-гай/-кай* кушымчалы хикәя фигыльнең берлектәге һәм күплектәге II заты баш җөмләнең хәбәре булып килгәндә, иярчен җөмләнең хәбәре шарт фигыль белән күрсәтелсә, киләчәктә эшләнәчәк эшләрне белдерә. «Кыйссаи Бүз йегет»тә: Йалғызым диб йығласа, күңел аулаб йөргәйсән, / Әгәр хезмәт бойырса, мәндәй булыб кыйлғайсән [Уразаев-Кормаши 1874, б. 31]. Әмма II затта әлеге фигыльнең мәгънә эчтәлеге шактый катлаулана: сөйләүче тыңлаучыга эшләнергә тиешле йомыш кушканда, бер үк вакытта ярдәмгә мохтаҗ булу, өмет итү, үтенү-ялыну төсмере дә салына: Башымдағы бүркемне моңлы булған анама / Үз қулыңдай биргәйсән, күңелен аулаб йөргәйсән, / Қулымдағы йөзекемне, дустым, қулыңа салғайсан, / Моңлы анамны күргәндә, безне искә алғайсаң [Уразаев-Кормаши 1874, б. 31]. Шуның белән бергә, сөйләүченең тыңлаучыга бирергә теләгән жиңелчә боеру, киңәш итүе дә *-гай* күрсәткечле фигыльнең II зат формасы белән белдерелә: Ханым, сүзем шул сиңа: амән-исән йөргәйсез / Алладан әмер килгәндә, сабырсыздан йаман йук, / Бигрәк сабыр қыйлғайсән, бер-ике көн қунақ без, / Үзеңез аны белгәйсез, қыйәмәт көн булғанда, / Йиргә халық тулғанда, шунда сез дә барғайсез, / Уғлыңны шунда күргәйсез, иманны қыл оҗмахда [Уразаев-Кормаши 1874, б. 58] һ.б.

*-гай* кушымчалы хикәя фигыльнең берлек һәм күплектәге III заты, билгеле шартлар үтәлгәндә, тәгаен булачак эш-хәлләрне белдерә. «Кыйссаи Бүз йегет»тә: Барсаң, кешеләр күргәйләр, қашына килеб торғайлар, / Жыйылған күб җәмәғатьләр бездин хәбәр сорғайлар [Уразаев-Кормаши 1874, б. 31] һ.б.

Г. Чокрыйның «Заммы назыйр» китабы (1888) *-гай* формасының әлеге мәгънәсенә нигезләнеп иҗат ителә: Замана ахры булса, нәләр булғай, / Дөньйаға төрлек-төрлек бәла тулғай, / Ғалимләр ғаҗиз булыб зарый қылғай, / Аңдин артық тәқый ғазаб таңлары вар... [Чокрый, 1888, б. 3] һ.б.

Г. Чокрый иҗатында *-р* формалы фигыль үзенең хәзерге заманны белдерү вазифасы белән кулланылышта була: ...Дәхи анлар мине бикяр сайырлар, / Хәқыйрьләрдән хәқыйрь бикяр санырлар... [Татар поэзиясе…, 1992, б. 333]. Бу юллардагы *-р* формалы фигыль хәзерге заманның дәвамлы, гадәти, кабатлаулы мәгънәсе белән файдаланылган.

*-р* формасының бу мәгънәсе аның киләчәк заманны белдерә торган мәгънәсе белән чиратлашып та кулланыла: Һаwада қаз китеб

барса, қараб күр: / Берен – алда тотар. Син дә сабақ күр: / Ийәрсәләр аңа туғры барырлар, / Чобалсалар – дулаб, чашыб қалырлар... [Татар поэзиясе…, 1992, б. 340]. Әлеге өзектәге *алда тотар* гыйбарәсендә *-р* формасы гадәти хәзерге заманны, ә *барырлар, калырлар* фигыльләрендә шул ук форма киләчәк заман мәгънәсен белдерә.

Г. Чокрый иҗатында *-р* формалы киләчәк заман *-гай* формасы белән дә чиратлаша: Без китәрмез, сүземез булғай хәләф... [Татар поэзиясе…, 1992, б. 337].

М. Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәт мәрсиясе»ндә, *-а* кушымчалы фигыль еш кабатлана торган гадәти эш-хәлләрне белдерә, аерым очракларда *-р* формасы белән алмаштырыла: Мән үзем бер дәрдмәнд диwанәмән / Қайда бер тәхқыйқ күрсәм қуанамән... [Акмулла, 1892, б. 3]; ...Бу сәбәбдән сезләргә сәлям йазам / Бу йақға килеб йатыр сезнең азан... [Акмулла, 1892, б. 6] һ.б. Шул ук мәгънәне белдерү өчен, *-р* формалы фигыль дә файдаланыла: Сүз чығар шағыйрьләрдән хикмәт берлән... / Һәр җандар сәйрән қылыр сәбилендә, / Былбыллар җәүлән қылыр сәрирендә... [Акмулла, 1892, б. 5] һ.б.

Мәгълүм булганча, Акмулла иҗатында, *-р* формалы хәзерге-киләчәк заман үзенең юклык мәгънәсе белән дә бик актив кулланыла, гадәттә *-а* формалы хәзерге даими-гадәти, кабатлаулы фигыльнең барлык мәгънәсен алып килә торган юллар белән чиратлашып бирелә: Ашқан бер ғалим чықса, йаманлаймыз, / Мәҗлесне ғайбәт илән тәмамлаймыз... / ...Йахшыны сүккән илән аты китмәс, / Йаман сүзнең күңелдән даты китмәс... / Саф алтынны нәҗескә буйау илән, / Нәҗес китәр, алтынның заты китмәс... [Акмулла, 1892, б. 12]. Икенче шигырьдә шул ук мәгънәне бирүдә *-бәс* формасы файдаланыла: Асылды сүккән менән аты китбәс, / Күңелдән җаман сүздең дағы китбәс, / Нәҗескә саф алтынды буйау менән, / Нәҗес китәр, алтынның заты китбәс / Қыйсық уқ атқан менән туры китбәс, / Күңелдән җаман сүздең куры китбәс... [Акмулла, 2001, б. 77]. Кайбер шигырьләрендә *-мас* формасы эзлекле булып кабатлана, шул әсәрнең эчтәлеген бирүдә кирәк булган сәнгатьчә чарага әверелә: Сауыскан, хаким булып, тутый булмас, / Җуқ илдең бузбаласы қоты булмас, / Бозаwы үлгән сыйырдың сөте булмас, / Җолдызы Саратандың Кавес булмас… [Акмулла, 2001, б. 73].

Акмулла шигырьләрендә *-р* формасы катгый киләчәк заманны белдерә торган мәгънәсе белән кулланыла: Жаманды күп үстерсәң – өмид кисәр, / Хызырдың қадрен белмәс тинтәк, исәр, / Залимдең золмы күп, күп симертсәңез, / Табақдан эттең башы чурчып төсәр, /

Җаманды түрә қылсаң – йортың бозар, / Ғақылсызны үстерсәң – ботын сузар... [Акмулла, 2001, б. 74] һ.б.

Шулай итеп, Акмулла иҗатында *-р* формалы хикәя фигыль хәзерге заманның гадәти мәгънәсе белән дә, киләчәк заман мәгънәсе белән дә файдаланыла, аның юклык төре дә актив кулланыла, сәнгатьчә чарага әверелә, әлеге шагыйрьгә генә хас булган үзенчәлекле сурәт ясый.

Шуның белән бергә, М. Акмулла иҗатында, Ә. Уразаев-Кормаши кыйссаларындагы кебек, хәзерге-киләчәк заман мәгънәсе *-ади, -айди* формалы фигыльләр белән күрсәтелә. Бу төр фигыльләр сөйләү моментында актуаль булган эш-хәлләрне белдерә: ...Күрәмез тирәзәдән мирзаларды / Үтәде қасымыздан сабай-сабай [Акмулла, 2001, б. 68]; ...Қатықсыз қара күҗә – эчкән асы / Эчкәндә тамчылайды күзнең йасы [Акмулла, 2001, б. 68].

Шул ук фигыльләр белән даими, гадәти, кабатланып тора торган эш-хәлләр дә белдерелә, барлыкта һәм юклыкта күрсәтелә: Адәм кямил булмади қайнап пешмәй / Мәхәббәт фәнҗанендән шәрәб эчмәй [Акмулла, 2001, б. 27]; ...Қара чебен сау җиргә күз салмайды [Акмулла, 2001, б. 48? 59]; ...Тыш таһәрәт алу менән эш бетмәйде [Акмулла, 2001, б. 55]/

*-р* формалы хәзерге-киләчәк заман фигыльнең төрле мәгънәләре Дәрдемәнд шигъриятендә сәнгатьчә яңгыраш таба. Гадәти, дәвамлы кабатлаулы мәгънәсе белән: Ни ғазизрәк – бу wатанмы? / Аh, туған каwмем ғазиз, / Ул мөқаддәс қан белән ул / Изге сөткә ни җитәр... / Сөт қалыр, wатан китәр, / Сөт қалыр, wатан китәр... [Дәрдемәнд, 1980, б. 92]. ...Исәрме җил туғай буйлап, / Җылармы қыз моңын сөйләп, / Көләрме шатланып, көйләп, / Ағач, таш эчләре шаңрап, / Киләдер бер нида йаңрап... [Дәрдемәнд, 1980, б. 79] һ.б. *-а, - а (дыр)* кушымчалы хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльләре дә шул ук мәгънәдә кулланыла: ...Шаулый диңгез... / Җил өрәдер... / Җилкәнен киргән кораб / Төн wә көндез / Ул йөрәдер: / Йул бара йат ил қараб... [Дәрдемәнд, 1980, б. 36].

Г. Тукайның беренче шигырьләрендә *-р* формалы хикәя фигыль хәзерге заманның төрле мәгънә төсмерләре белән кулланыла. «Шәкерт, яхут бер тәсадеф» шигырендә, күрү вакытында башкарыла торган эш-хәлләрне белдерә: Күрәм: бер талиби тәхсыйлә варыр, / Утырыб хәл җыйар да тағы арыр... / ...Суықның зәмһәрире, зәһре кискен, / Тағы туқтар, тағы атлар у мескен [Тукай, 1955, т. 1, б. 13]. «Пушкинә» шигырендә: Қасавәт кәлмәйүр кальбә: сәнең шиғрең мөнафиһа, / Нәчек кем шәмсә қаршы парлайур дөньйа wә мафиһа [Тукай, 1955, т. 1, б. 22]. «Мөхәрриргә» шигы-

рендә: Бәхтийәр сән дүрт җәридә сахибе улмакла сән / Чөн акар һәр дүрт тарафдан мәғрифәт нәһри сәңа [Тукай, 1955, т. 1, б. 40] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, *-р* формалы хикәя фигыль, нигездә, үзенең гадәти, даими, кабатлаулы, тәмамланмаган мәгънәсе белән ешрак кулланыла, беренче өзектә генә актуаль мәгънәсендә файдаланыла.

Билгеле булганча, шул ук шигырьләрендә *-р* формалы хикәя фигыль үзенең киләчәк заманны белдерә торган мәгънәсе белән дә кулланыла: ...Сәнең дә йөксәлер бер көн мәқамең, / Йазылыр, ихтимал, алтынла намең... / ...Бәлеш илә ғыйлем бергә җыйылмас, / Хирыслы адәм үлгәнче тыйылмас... (Шәкерт, яхут бер тәсадеф); ...И каләм, сәндән кәлер һәп бәхтемез, иқбалемез, / Бәкләнер дүрт күз илә лотфында истиқбалемез (И каләм!) һ.б.

Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, Г. Тукайның беренче шигырьләрендә *-р* формалы хикәя фигыль, киләчәк заманны белдереп, үзенең парадигматик мәгънәсе белән дә һәм, шулай ук, төрле модаль төсмерләр белән катлауландырылып та кулланыла, эстетик эчтәлекне алып килә торган сәнгатьчә чарага әверелә, алга таба әлеге фигыльнең, нигездә, киләчәк заманны белдерү мәгънәсе активлаша.

Г. Тукай иҗатында *-а* кушымчалы фигыль еш кабатлана торган гадәти эш-хәлләрне белдерү мәгънәсе белән кулланыла: ...Йазам, йуқ, туқтамыйм мин һич, алардан бер дә қот чықмый... / ...Чебен җанымны чын йулда бирәм беңкәррә, қызғанмыйм... [Тукай, 1955, т. 1, б. 35]; .... Сөйәм сезнең сызылған қашыңызны... / Йаратам тәмле, татлы сүзеңезне... / Дийәм, әстәғфирулла, анда кермим, / Китәм әғрафә тиз, бер ан дә тормыйм... [Тукай, 1955, т. 1, б. 37] һ.б.

Г. Тукай «Казанга кайтыш» дигән мәкаләсен түбәндәге «бәет» белән тәмамлый: Нумирың матур булса, күсе булғай, / Һәр матурда начар йақның берсе булғай, / Ансы булып җитмәсә дә, монсы булғай / андыйн йыптық, мондыйн йыртық тунларым бар. / Бер адәмнең чын дошманы күсе булғай, / Икенчесен йөдәтүче кеше булғай, / Һәркемнең үзенчә бер эше булғай, / Андыйн сүтек, мондыйн йыртық тунларым бар... [Тукай, 1956, т. 3, б. 139]. Аңлашылганча, әлеге өзек Г. Чокрыйның мәгълүм әсәренә нигезләнә, шагыйрьнең яшь аралаш көлүен тасвирлауда бер чара булып күтәрелә.

*-р* һәм *-а* формалы фигыльләрнең бер үк мәгънә белдереп кулланылуын башка шагыйрьләр иҗатында да күзәтергә мөмкин.

Г. Сәмитова шигырьләрендә *-р* формалы хикәя фигыль үзенең хәзерге заманны белдерә торган мәгънәсе белән файдаланыла: «Бән

йыгламый, кем йыгласын» шигырендә: Күзеңдә тулы қанлы йәш, / Нидән йығларсән, қаләм қаш? / Бән йығламый, кем йығласын? / Аwылым йырақта, башым йәш. Әлеге шигырьдә бирелә торган мәгънә икенче шигырьдә җанлы сөйләмә вариантта язылa, анда *-а* формасы файдаланыла: Идел буйы йәшел таш, – Ник йылыйсың, йәш туташ? / Бәхетләрем булмағанға, Эчем сағыш, күзем йәш... [Татар поэзиясе…, 1992, б. 383].

Г. Рәхмәтуллина шигырендә дә *-р* формалы фигыльнең хәзерге гадәти мәгънәсе киләчәк заманны белдерү мәгънәсе белән параллель кулланыла: «Аналарга йәднамә» шигырендә: Дүрткә килде бала, йөгрә, дөньйа йақты урамда, / Күрер тирә, алыр, ашыр, тиң йулдашы булғнда, / Үтәр аңар хуш холық бу чағыңда үскәндә, / Ғадәт күркәм аңа қалыр, тирә күркәм булғанда / Бишкә килде: белә, аңлый, ақча сорый базарға, / Қылма боныйә ...хурлық йулы ғадәт қалыр аңарда... [Татар поэзиясе…, 1992, б. 391] һ.б. Шулай итеп, XIX гасырның беренче һәм икенче яртысында иҗат ителгән тезмә әсәрләрдә хәзерге-киләчәк заманны белдерә торган *-р* формалы фигыльләр эзлекле рәвештә хәзерге заманның барлык мәгънәләре белән дә һәм шулай ук киләчәк заманны белдерә торган мәгънәсе белән дә кулланылышта була; *-а* формалы фигыльнең киләчәк заманны белдереп файдаланылуы шактый чикле икәнлеге күренә, бу форма халыкчан сөйләмә юнәлешне саклаган хәлдә әдәбиләшкән тасвир чарасы була.

Тезмә әсәрләрдән аермалы буларак, чәчмә кыйссаларда *-р* һәм *-а* формалы фигыльләрнең һәм хәзерге, һәм киләчәк заманны белдереп файдаланылуы, *-р иде, -а иде* формалы үткән заман фигыльләрнең вазифасына якын булуы, ягъни тәгаен генә нинди мәгънә белдерүенә караганда, риваятьләрдән килә торган билгеле мәгълүм хәбәрләрне, шартлы сөйләүче тарафыннан гадәти, дәвамлы хәлләрне укучыга кабатлап, бәян итүдә уңайлы бер мөһим алым булуы, кеше сүзен сөйләп хикәяләнә торган кыйссаларда вакыйганы алып бару өчен, уңай бер чара булуы күренә. Бу төрдәге әсәрләрдә *-р* һәм *-а* формалы фигыльләрнең дә шушы ук вазифаны үтәп, хәзерге һәм киләчәк замannарның берсе икенчесенә бәйле хәлдә баруы мәгълүм була.

К. Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы» (1868): Тәварих китапларында ривайәть қылып йазалар ки..., дип *-а* формалы фигыльнең III заты күплек саны белән башлана [Насыйри, 1975, б. 221], кеше сүзен сөйләү рәвешендәге хикәяләү I заттан дәвам ителә: Йегет әйтде: без ни өчен қазыйға барырбыз, ...хатын айырмақ бездә зур гайеп эшдер, булмам, айырмам [Насыйри, 1975, б. 233] һ.б. Мисаллардан

күренгәнчә, хәзерге заманны белдерү өчен *-р* (барырбыз, булырмын) һәм *-а* (булмам, айырмам) формалы фигыльләр файдаланыла. *-а* формасы киләчәк заманны белдерү мәгънәсе белән дә кулланыла. *-р* формалы фигыль дә киләчәк заманны белдерү мәгънәсе белән файдаланыла: ...мине хәләллеккә қабул итсәң, атаңны үтереп, сине атаң урынына патша итәрмен [Насыйри, 1975, б. 245]; шунда ук *-р* формалы фигыль хәзерге актуаль мәгънәсе белән бирелә: Әүwәлән мин үзем гаһед wә йәмин итәрмен (билләһи, валлаһи, таллаһи), мин бу сүзләрне чын күңелем белән, сине җаным кебек күреп сөйләрмен wә бу сүзләремә һичбер хилафлық итмәсмен, син дәхи миңа йәмин ит, инандыр... [Насыйри, 1975, б. 223] һ.б. Шул ук мәгънәләр II зат белән дә бирелә: И җаным, ...қайғылы торырсың, ...атаңны ничек үтерим дисәң, ...соңыннан никах иттереп, хатын итәрсең... [Насыйри, 1975, б. 224] һ.б. Күренгәнчә, хикәяләү барышында *-а* һәм *-р* формасы белән күрсәтелә торган хәзерге һәм киләчәк заманнар, берсе икенчесенә бәйле хәлдә, *-ды, -а иде, -р иде* формалары белән бергә дәвам ителә.

Әлеге мәсьәләне җентекләбрәк аңлатырга мөмкин. Иярчен җөмләнең хәбәре боерык яисә теләк фигыль белән бирелгәндә, I зат *-р* формасы киләчәк заманны белдерә: И ахмақ уғылан, мин телим сине тәхеткә мендереп патша итәргә, ...инде атаңа сөйләрмен [Насыйри, 1974, б. 224]. И хуҗа мин синең белән Багдадқа барырға телим, йулда сиңа хезмәт итәрмен, қабул ит, диде [Насыйри, 1974, б. 232]. Син исән бул, син исән булсаң, мин сиңа һәркөн килермен [Насыйри, 1974, б. 240]. Шулай итеп, татар прозасын хикәяләүнең беренче чорында *-р* формалы хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең I заты, нигездә, диалогик сөйләмдә, башлыча, киләчәк заман мәгънәсе белән кулланыла. Иярчен җөмләнең хәбәре боерык фигыль булганда, II зат та киләчәк заманны белдерә: Үз башыңны қотқарырға чарасын күр, бу патшалығың қулыңнан китәр. Тизрәк ул сине үтермәс борын, син аны элгәре үтер, яwызлығыңдан имин булырсән [Насыйри, 1974, б. 225]; Үзең хисап ит, җансыз кеше қоллық итә белерме? Әгәр сиңа нәфәкасыз ғаскәр кирәк булса, болар җитәр. Йуқ дисәң, адәм булып жаны булған зат ашамак-эчмәк теләр [Насыйри, 1975, б. 226] һ.б.

*-р* формалы хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең II заты, диалогик сөйләмдә, гадәттә, сөйләү моментында актуаль булган хәзерге заман мәгънәсе белән файдаланыла: Уғлан… хуҗасына әйтде: Сән нә бойырырсән, фәрман синеңдер [Насыйри, 1975, б. 222]; И җаным,

аһ минем солтаным, ...қайғылы торырсән [Насыйри, 1975, б. 223]; И хужа, бу сүзне икенче мәртәбә әйтмә, йукса үзең белерсән [Насыйри, 1975, б. 227] һ.б.

*-р* формалы хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең III заты да хәзерге заман мәгънәсе белән активрак, хикәяләүне алып баруда, билгеле бер дәрәҗәдә, ешрак кулланыла: Күрде ки, хатын қызыл қанға буйалып утырыр [Насыйри, 1975, б. 224]; И падишаһ, миннән wазифасыз адәмнәр сорадың, менә инде бу йегетләр бер дә wазифа сорамаслар, һаман патшаға қоллық итәләр [Насыйри, 1975, б. 226]. һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, *-р* формалы киләчәк заман сөйләү моментыннан соң ук башкарыла торган эш-хәлләрне дә белдерә һәм шулай ук төрле модаль төсмерләре белән дә файдаланыла.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда (1872–1881): Раwийәне әхбар wә накыйләне асар ошбу тарик үзрә риwайәть қыйлурлар ки... [Насыйри, 1898, б. 3]; ...хәтта хикәйәт қыйлынур ки, ...һәр көн өйләгәчә дәрес уқыр, wә шәкердләренә дәрес биреб, андан соң балалар белән уйынға чығар иде [Насыйри, 1898, б. 4]; ...Шөйлә риwайәть қыйлурлар, Дауд ғаләйһи әссәлам заманында бер адәм бар иде, исеменә Фисағурис дийерләр иде... [Насыйри, 1898, б. 5] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, кабатлана торган гадәти эш-хәлләрне белдерә торган хәзерге заманның мәгънәсе *-р* формалы фигыль белән белдерелә, *-р иде* формасы белән үткәнгә каратыла һәм эзлекле рәвештә бара, аңа караганда *-р* формасы сирәгрәк файдаланыла: ...Ул мәғарә йылда бер мәртәбә мөғайан көндә ачылыб, өч сәғать микдаре ачық торыр, ...хәтеренә ниқадәр ғыйлемлек ала белсә, алыр, ...бу мәғарәгә бу йыл кереб булмас [Насыйри, 1898, б. 5]. Юклыкта *-мас* кушымчасы ала, мисаллардан III зат берлектә һәм күплектә икәнлеге күренә.

Хикәяләү барышында *-р* формалы фигыльнеж кабатлаулы гадәти эш-хәлләрне белдерә торган, хәзерге заман актуаль мәгънәсендә кулланылуы эзлекле рәвештә дәвам ителә:... Ғайәть кирәк булғанларын суған суы белән йазып алдылар. Чөнки суған суы белән йазғач, хаҗәт wақытта ут өстендә тотсалар, йазуы заһир булыр [Насыйри, 1974, б. 211–212]. ...Wә дәхи бу йегетләр һәммәсе бер-беренә охшар, бер сыйфатта wә бер сурәттә телсез йөрерләр. ...Җиде көндә мондайын олуғ хаммам бина қыйлмақ ничек мөмкин булыр?...һәрберсе җиде көндә бер йөк ақча қазаныр [Насыйри, 1974, б. 216]. Җөмләләрдән аңлашылганча, *-р* формалы фигыльләр эзлекле рәвештә кабатлаулы, гадәти дәвамлы хәзерге заман мәгънәсендә кулланыла. Алынган ми-

саллардан күренгәнчә, хәзерге заманның сөйләү моментына туры килгән мәгънәсен белдерү өчен, *-р* формасының эзлекле баруы, *-а* формалы фигыльнең II зат күплектәге формасының: Безгә хәбәр бир, ул ничек мәғарәдер, аны ник халыкқа хәбәр итәсез [Насыйри, 1974, б. 210] һәм I зат берлектәге формасы бер мәртәбә файдаланылуы күренде: ...ни хезмәтеңез бар, бойырыңыз, җибәрәйем, хәзер китерсен... [Насыйри, 1974, б. 217].

Шулай ук, сүз сөрешеннән аңлашылганча, *-р* формасының билгесез киләчәк заман мәгънәсендә дә актив кулланылуы да күренә: Бу мәғарәгә бу йыл кереп булмас, чөнки өч сәғатьтә ни хасил булыр. Киләчәк йылға қалып, ...тәмам моталәға қыйлырмыз...; Иртәгә мәғарә қапусы ачылыр, агяһ булыңыз... [Насыйри, 1974, б. 211] һ.б. Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, *-р* күрсәткечле хикәя фигыль, хәбәре шарт фигыль белән белдерелгән иярчен җөмләдән соң килгән баш җөмләнең хәбәре булып килгәндә һәм шулай ук боерык, теләк наклонениесендәге фигыльләрдән соң яисә сәбәп-максатны аңлата торган чаралар ярдәмендә белдерелгән иярчен җөмләдән соң килгәндә, яки контекстка туры килгән лексик чаралар белән ныгытылганда, әлеге фигыль белдерә торган эш-хәлләрнең киләчәктә үтәләчәген аңлата.

Шуның белән бергә, «шөйлә риwайәть қыйлалар ки...» дигән җөмләдән аңлашылганча, хәзерге заманның кабатлаулы гадәти синтагматик мәгънәсенең *-а* формалы фигыль белән белдерелүе, ягъни *-р* формасын алмаштыра алуы аңлашыла [Насыйри, 1974, б. 298]. Хикәяләү барышында, эзлекле булып, *-ды* формалы фигыль тезелеп барганда, *-а* формалы хәзерге заман фигыльнең шул ук мәгънәсе белән файдаланылуы күренә: Хәлвәфруш йегет бер заман фикер итеп қалды wә хәйрат дәрьйасына талды [Насыйри, 1974, б. 227–228]. Фигыльнең хәзерге заманга куелуы үткәндә булган дип сөйләнә торган хәлләрне укучының күз алдына бастыра: ...дер-дер қалтырый башладылар, ...һичберсе җаwап бирмәйенчә, тизрәк кийенеп, билләрен бәйли-бәйли, шакор-шокыр чығып китәләр, ...урамнарда очраған халық көлешеп, артларындан ийәреп баралар [Насыйри, 1974, б. 250]. ...Әбүгалисина күрде, болар гайәть тәфтиш қыйлып, үзен wә хәлвәфрушны қулға төшермәгә иҗтиһад қыйлалар [Насыйри, 1974, б. 252] һ.б. Шулай итеп, рәттән тезелеп бара торган һәм монотонлы сөйләмне барлыкка китерә торган *-ды* формалы үткән заман хикәя фигыльләрдән соң килә торган *-а* кушымчалы хикәя фигыльнең III заты вакыйганы укучы күреп

торган хәлгә куя, эш яки хәл персонаж сөйләп торганда бара кебек тәэсир барлыкка килә.

К. Насыйри кыйссаларында персонаж сөйләме рәвешендә бирелә торган өзекләрнең аерым җөмләләрендә I зат барлык һәм юклыкта *-а* формалы фигыльләр кулланыла: Син һич сорама, мин сөйләмим [Насыйри, 1974, б. 277] һ.б. *-а* формалы фигыльнең I зат күплектәге мәгънәсе дә шундый ук вазифа үтәп, сөйләү вакыты белән туры килә торган мәгънәдә кулланылуы күренә, ягъни хәзерге заманны белдерү өчен *-а* формалы фигыльләрнең файдаланылуы аңлашыла. Бу вазифаны үтәгәндә, ешрак тулы кушымчалы I зат берлек санындагы фигыльләрнең кулланылуы күренә: айағым белән йөреб китәмән, үземне барыр күрәмен, барамән [Насыйри, 1974, б. 252], мин шөйлә гөман итәмән [Насыйри, 1974, б. 263]. Юклыкны белдергәндә кыска төрен ала: ашамыйм дип әйтергә һич қадир булмайын... [Насыйри, 1974, б. 262] һ.б. Сүз сөреше *-айым/-им* кушымчалы теләк фигыльләре белән дәвам ителә: өйрәтәйем, ...wә санагатьләр күрсәтим [Насыйри, 1974, б. 227]; ...Әгәр фәрманыңыз булса, баш өсте, бу хезмәтне әда қыйлайым [Насыйри, 1974, б. 243]. ...ни күрсәм, хәбәр бирәйем дигән җөмләдә [Насыйри, 1974, б. 275] *-а* формасының киләчәк заман мәгънәсен белдерүе аңлашыла.

II затның берлек саны сәнгатьле проза әсәрләрендә, I зат берлек саны кебек үк, асылда, диалогларда файдаланыла һәм үзенең төп-парадигматик, ягъни сөйләү моментында актуаль булган мәгънәсе белән кулланыла. Мәсәлән, «Кырык вәзир»дә: ...сиңа ни булды, ни өчен һичбер сүз сөйләмәйсән, ...инде ник рәнҗисең? һ.б. Бу фигыльнең әлеге мәгънәсе аның дәвамлылыкны, гадәтилекне, кабатлануны белдерә торган мәгънәсе белән бергә чиратлашып бара: ...wә һәм син үзең дә йалғанны күп сөйләшәсән, һәр кичә уғланны үтерермән дийәсән, үтермисән. ...Син һәрwақыт падишаһның инғаменә лайык буласән, әмма безнең һич халемезне сорамыйсән [Насыйри, 1898, б. 19] һ.б. «Әбүгалисина»да: ...йуқ сүзләр белән балаларны алдаған кебек итәмусән [Насыйри, 1974, б. 229]; ...син ғаҗәиб сүз әйтәсән [Насыйри, 1974, б. 233] һ.б.

II затның күплек саны да, нигездә, шундый ук максатта берлек саны белән чиратлашып файдаланыла: ...аны ник халыққа мәғлүм итәсез?... [Насыйри, 1974, б. 210]; ...Әй шаһым, йуқ йирдә үзеңезгә зәхмәт бирәсез. ...үзеңез беләсез илчегә үлем йуқ диләр [Насыйри, 1974, б. 264] һ.б. *-а* формалы хәзерге заман хикәя фигыльнең II зат берлек саны *-сән, -сын,* күплек саны *-сез* кушымчалары белән кулла-

ныла, сорау күрсәткече зат-сан кушымчасына кадәр кушыла. Бу кыйссада -а формалы хәзерге заман фигыльнең II зат берлек һәм күплеге теләк, киңәш, җиңелчә боеру, үтенү-ялваруны белдерә торган мәгънәсе белән дә шактый актив файдаланыла: Әгәр мәғкул күрсәңез хуш ула, бу тарафларға кәрәм бойырасыз. Рәхим итәсез, ике-өч көнлек ғомерне бергә кичерәйек [Насыйри, 1974, б. 245] һ.б.

*-а* формалы фигыльнең I һәм II затлары сирәк очракларда киләчәк заман мәгънәсендә, киләчәк заманны белдерә торган фигыль белән чиратлаша: ...сиңа күз күрмәгән, қолақ ишетмәгән ғаҗаиб һөнәр wә санәғатьләр күрсәтим. Бу кич кибетеңдә қал, йарар, барырмын [Насыйри, 1974, б. 227] һ.б. *-р* формалы фигыль дә киләчәк заманны белдерү максатына яраша башлый: И шаһе җиһан, сихер нәпақлек белән wә яwызлық белән хасыйл булыр. Әмма симийә пақлек wә рийазат белән хасыйл булыр [Насыйри, 1974, б. 231]; ...Һәр қачан аның әмеренә мотыйғ бул, күп файда күрерсең [Насыйри, 1974, б. 233] һ.б.

*-а* кушымчалы хәзерге заман хикәя фигыльнең II зат күплек саны кайбер публицистик мәкалә һәм тәрбия мәсьәләләренә багышланган хезмәтләрендә файдаланыла, гадәттә, вакытка бәйле булмаган гадәти яки кабатлана торган эш-хәлләрне белдерә. «Казан халкына мөрәҗәгате» мәкаләсендә: Бөтен ғаләм халқы ғыйлем артдырырға һиммәт бағламышлар икән, шундыйын заманда сез ғыйлемнең хилафына сәғый қыйласыз. ...Һәр телнең қағыйдәсе бардыр, әмма сез мондый нәрсәне инкяр қыйласыз, тел үгрәнүнең тариқын белмисез... [Насыйри, 1974, б. 39].

К. Насыйриның сәнгатьле прозасында *-а* формалы фигыльнең III заты, парадигматик-актуаль мәгънәсе белән файдаланыла: Әбүгалисина күрде, ахыр асалар [Насыйри, 1974, б. 254]. Әмма бу хәл күбрәк диалогик сөйләмдә күзәтелә: ...Анасы әйтте: Хәзердә бер дәрwиш утырып сату итә, – диде [Насыйри, 1974, б. 233]; ...йоқлап йаткан җиреннән алып китәләр, таң беленгәч йәнә китереп куйалар [Насыйри, 1974, б. 244] һ.б. Шул ук диалогик сөйләмдә гадәти хәзерге заманны белдерү өчен *-адыр* формасы уңайлырак дип табыла: ...wә ул җәзирә эчендә ут барлығын беләдер икән дә, ут эчендә адәм ничек торсын, аны белмидер икән [Насыйри, 1974, б. 248]. Бу җөмләләрдә гадәти хәзерге заманны белдерү өчен, *-а, -адыр, -р* формалы фигыльләр кулланылуы игътибарны җәлеп итә. Димәк, хәзерге заманны белдерү өчен файдаланыла торган *-р* формасының вазифасы *-адыр* формалы фигыльгә йөкләтелә башлавы чагылыш таба дип әйтә алабыз.

К. Насыйриның фәнни хезмәтләрендә *-адыр* формалы III заттагы хәзерге заман хикәя фигыльнең нәкъ менә шул, ягъни даими, эзлекле, кабатлаулы эш-хәлләрне белдерә торган мәгънәсе киңрәк реальләшә. «Фәвакиһелҗөласә» китабында: ...шулай қурқақ wә йөрәксез кешеләр бар ки, чыпчық таwышы ишетелсә, қоты чыға, чебен бызылдаса, йөрәге куба, ишек шығырдаса, сискенеп китә, күзеңне бер мәртәбә тутырып қарасаң, һушы китә, җил белән тәрәзә қапқачлары шалтыраса, йурған астына башын тыға. [Насыйри, 1975, б. 251]. «Истыйляхате җәгърәфия» китабында: ...җәғрәфийә китапларына қарап уқып өйрәнүче адәмнәр, ил гизүчеләр кебек, бер сулуда бөтен дөньйаны гизеп, тамаша қылып чығадыр [Насыйри, 1975, б. 83]. «Мәнафигъ әгъза вә кануны сыйххәт»тә: Дәхи дә җил wә һаwа тирене кисәдер wә чығасы тирне мәнгы қыладыр. Әгәр чығасы тир чықмый қалса, күп аwырулар пәйдә буладыр [Насыйри, 1975, б. 69]. «Гөлзар вә чәмәнзар» китабында: Аwыл халқының тәҗрибәле адәмләре дару үләнен җыйсалар, wақытын белеп җыйалар һәм сақлый беләләр [Насыйри, 1975, б. 77].

Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, *-а* һәм *-адыр* кушымчалы хәзерге заман хикәя фигыльнең III заты даими, эзлекле, һәрвакыт булып тора торган, ягъни вакытка бәйле булмаган мәгънәсе белән кулланыла. Аңлашылганча, *-а* формалы фигыльнең, *-а иде* үткән заманы белән чагыштырганда, барлык мәгънәләре белән дә кулланылышта булуы күренә.

Шуның белән бергә, К. Насыйриның фәнни-дидактик хезмәтләрендә *-р* формалы фигыльләр дә шактый киң урын ала. «Әхляк рисаләсе»ндә (1881): Камаль адәмилек дәхи изге холықлы булмақ wә йаwыз холықдан сақланмақ белән хасил булыр. ...Йәшь ағач һәр ниқадәр кәкре булса да, төз итмәк асандыр. Шуның кебек, адәм дәхи кечкенә wә йәшь wақытда тәрбийәне қабул итмәке асан булыр [Насыйри, 1975, б. 103]; ...Атаңа, анаңа хөрмәт итмәсәң wә хәлфәләреңне риғайә қыйлмасаң, ғомердә изгелек күрмәссән [Насыйри, 1975, б. 6] һ.б. «Китаб-әт-тәрбия»дә (1891): Бәс, әй уғыл, нәфсең симергән сайын, ул сине һәлакәткә тартыр. Дөньйада баһадир шул кешедер ки, нәфесен җиңәр [Насыйри, 1975, б. 135]. Мисаллардан аңлашылганча, *-р* формасы даими, гадәти хәзерге заманны да, сөйләү моментыннан соң башкарыла торган эш-хәлләрне дә белдерә торган мәгънәләре белән кулланыла.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1879) әсәрендә, хикәяләүне алып бара торган *-р иде* формасы белән рәттән, абзацларның башламында, «Әбүгалисина кыйссасы»ндагы (1872) ке-

бек, хәзерге заманның даими, гадәти мәгънәсе белән *-р* формасы файдаланыла: Равиан асар wә нақыйлан дәр нәсар шундағ риwайәть wә мондағ хикәйәт қылырлар кем, [Татар әдәбияты, 1957, б. 287]. Рави әйтер ...күрделәр кем, бер дәрwиш хуш аwаз илән қычқырып әйтер кем, ...Күрделәр кем, пақ киемнәр кимеш, ...бер дәрwиш утырыр. Һичкемгә қарамый, йазу йазар, ...синең бер қыз балаң булып, wәзирнең ир баласы булыр... [Татар әдәбияты, 1957, б. 289] һ.б.

Бу кыйссада, *-р* формалы хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең II һәм III затлары да, I заты кебек үк, сөйләү моментыннан соң башкарылачак эш-хәлләрне белдерү мәгънәсе белән эзлекле рәвештә тезелеп бара: Һәркем миңа мең алтын сәдақа ихсан қыйлса, ходай тәбарәкә wә тәғалә ул кемсәнең күңелендә ни мақсуды булса да, бирер. ...И адәм, ошбу қаләмне тотып, күңелеңдәге сереңне уйла, ғыйлемлекнең теләwе буйынча ниләр заһир булыр [Татар әдәбияты, 1957, б. 288]. ...Әгәр бер-берсеннән айырсаңыз, ...қыйәмәткәчә телләрдә хикәйәт улып сөйләнер [Татар әдәбияты, 1957, б. 289] һ.б. Бер-ике мәртәбә *-а* формалы фигыльнең I һәм II затлары киләчәк замманны белдереп кулланыла: ...Әгәр синнән бүтән йар сөйсәм wә ғайрегә күңел бирсәм, морадыма җитмәйен [Татар әдәбияты, 1957, б. 293]. ...Әгәр дә сез дә бездән бүтән йар сөйсәңез, Хак тәбарәкә wә Тәғаләдән теләймәз ки, сез шул сәғатьдә һәлақ буласыз, – диде... [Татар әдәбияты, 1957, б. 292–293]. Аңлашылганча, *-р* формасының билгесез киләчәкне белдереп кулланылуы кыйссаның чәчмә өлешендә, тезмә өлешенә караганда, эзлеклерәк кулланыла.

«Әбүгалисина кыйссасы»ндагы кебек үк, бу кыйссада да *-а* формалы хәзерге заман фигыльнең II зат берлек һәм күплеге теләк, киңәш, җиңелчә боеру, үтенү-ялваруны белдерә торган мәгънәсе белән файдаланыла: ...Әмма сезләр қыйссаны бу тарафтан тыңлаңыз [Татар әдәбияты, 1957, б. 292], ...Әгәр қыз бала булса, исемен Зөһрә қуйарсыз. Әгәр ир бала булса, исемен Таһир қуйәсән һәм боларны бер-берсиндән айырмай икесен бер йирдә тәрбийәләб үстерәсез һәм бунлар бәлыйғ булғанларында,... қызыңны Таһиргә бирәсән [Татар әдәбияты, 1957, б. 289] һ.б.

Г. Фәезхановның «Татар теленә кыскача гыйльме сарыф» (1887) хезмәтендә *-а* һәм *-адыр* формалы фигыльләр, К. Насыйриның фәнни хезмәтләрендәге кебек, даими, кабатлаулы хәзерге гадәти мәгънәсе белән кулланыла, ләкин *-а* формасының ешрак кабатлануы күренә: ...Ошбу йир йөзендә адәми затдан ничә төрле халықлар бар ки,

аларның һәр қайусы үзләренә бер хас тел белән сөйләшәләр. Һәр кеше үзенең туған-үскән wақытындағы өйрәнгән телене ғыйльме сарыф wә нәху қағыйдәләрендән башқуқ сүзләрне дөрест сөйләшә, хата булғанда да бик аз wә надир wақыйғ була [Фәизхан, 1887, б. 2].

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда (1887), күпчелек хикәятләр дә хәзерге-киләчәк заманны белдерә торган *-р* формасының, К. Насыйри кыйссаларындагы кебек үк, риваятьләрдән билгеле мәгълүм хәбәрләрне, шартлы сөйләүче тарафыннан, гадәти, дәвамлы хәлләрне укучыга кабатлап, бәян итүдә уңайлы бер алым буларак кулланылуы аңлашыла. ...Тутый әйтде: шул рәwешчә риwайәт қыйлыныр ки, [Фәизхан, 1896, б. 12]; Тутый әйтде: борынғылардан шул рәwешчә риwайәть қыйлыныр кем, [Фәизхан, 1896, б. 42]; Тутый әйтде: шул рәвешле нәқыль булыныр кем [Фәизхан, 1896, б. 48] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, *-р* кушымчалы фигыльләр хәзерге заманның гадәти, эзлекле рәвештә дәвам ителә торган мәгънәсен аңлаталар, әмма аларның категорик үткән заман фондында бирелүләре, бу мәгънәне сөйләм вакытында актуаль булган төсмере белән дә баета. Әлеге форманың күп кенә кыйссаларны хикәяләүдә төп көч булып торганлыгы мәгълүм. Башлам җөмләләрдәге *-р* кушымчалы фигыльлә*р бар иде, юк иде* кебек хәбәрлек сүзләр белән бирелгән тезмә хәбәрләр, бер-ике мәртәбә *-ган, -мыш* формасы белән алмаштырыла: Тутый әйтде: әүwәлге заманда һинди йортында бер сәүдәгәр бар иде, [Фәизхан, 1896, б. 10]; Тутый әйтде: әүwәлге заманда тарих китапларында шул рәwешле йазылғандыр ки, [Фәизхан, 1896, б. 14] һ.б.

Әлеге кыйссаларда *-р/-мас* формалы фигыль актуаль мәгънәсе белән дә кулланыла: Иренә әйтде: Гәрчә бу айәть кәримә мәфһүменчә ...ошбу йир йөзендә булған һәр җан ийәсенең ризықы Алла Тәғаләдән ирешер дийүр, ләкин бу дөньйада сәбәбсез һич нәрсә булмас... [Фәизхан, 1896, б. 24] һ.б. Диалогик сөйләмдә исә әлеге вазифаны *-а* формалы фигыльләр үти: ...Әй Барый Тәғалә, кямил мәрхәмәтеңә йалынырмән ки, Тутыйны тергезәсән [Фәизхан, 1896, б. 13]; Әй Әбүәлмәҗид, бу төрле мағнәсез сүзләрне ник сөйлисән? [Фәизхан, 1896, б. 46]. Мисаллардан күренгәнчә, тулы кушымчалы беренче зат берлек сандагы *ялынырмән* сүзе дә II зат *сөйлисән* сүзләре дә хәзерге заманның сөйләү моментында башкарыла торган эш-хәлләрне белдерү мәгънәсе белән кулланыла.

Шулай итеп, татар прозасының кеше сүзен сөйләп хикәяләүнең беренче чорында *-р* формалы хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең

III заты, диалогларда кулланылганда, әлеге фигыльнең I һәм II затлары кебек үк, хәзерге заманның парадигматик мәгънәсе белән, абзац башламнарында даими, гадәти, кабатлаулы мәгънәсе белән файдаланыла. Һәр өч заты да, барлык кыйссаларда да, *-р* формалы фигыльнең киләчәк заманны белдерә торган мәгънәсенә караганда, сан ягыннан чикле булуы күзәтелә. Димәк, бу вакытта ук *-р* формасы киләчәк заманны белдерү өчен ныклы юнәлеш ала.

Татар прозасының автор үз сүзен сөйләп хикәяләнә торган икенче төре М. Акъегетнең «Хисамеддин менла» дигән милли романы белән (1886) башлана [Татар әдәбияты..., 1985, б. 291]. Бу әсәрдә бара торган вакыйга-хәлләр акыллы кешеләрнең сүзләрен кабатлап сөйләү рәвешендә түгел, ә реаль тормыштан алынган яисә шулай булырга тиеш дип ышанган күренеш-гамәлләр авторның үз исеменнән сөйләп хикәя ителә, хикәяләнү җанлана һәм затлана. Автор, вакыйганы сөйләүче кеше буларак, үзе алгы планга чыга, укучысына үзенең йөзен ача, аңа мөрәҗәгать итеп сүзен башлый, әсәрдә сөйләнелә торган хәлләргә, персонажларына, аларның эш-гамәлләренә карата үзенең мөнәсәбәтен турыдан-туры белдерә бара; әсәрдә хикәяләнәчәк хәлләрнең кайда, кайчан, нинди җирлектә баруын тәгаенләп күрсәтә, күренешләрнең тәртибен, хәрәкәтен билгели, аңлатма бирә, укучысына эндәшә. Җанлы автор сөйли башлаганчы, әсәрнең үзәгендә билгеле бер хакыйкать, изге фикер ята иде, ә хәзер шул фикерне әйтүче үзе мәйданга чыга; укучыга җиткерелергә тиешле сәнгати фикер гомумилектән котылуга йөз тотыла, аерым шәхеснең рухы белән өртелә.

Автор укучысына эндәшеп, үз исеменнән сөйләп барганга күрә, хикәяләүдә хәзерге заманны белдерә торган фигыль формалары активлаша: ...адыны фаш итмәкдән чикенәйүрез, анчақ хикәйәмези йиңел аңлатмак өчен, адыны «Н» хәрефе илә ишарәт идәмез [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 45]; «Н» карьйасына қайтамыз, хөрмәтлү укуҗыларым ...Ниһаять, шимди морадына ирешдекене күрәмез [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 38] һ.б. *-р* формалы фигыльнең хәзерге заманны белдерүе дәвам ителә: ...Җомға көн намаздан әүwәл кәндү ханәсендә «Тәфсире бәйзави» китабыны моталаға қылыр. ...Нурлы wә күк күзләре сәтрә бә сәтрә сәхифәйе йөгереп кәчәйүрләр. Башында бархат тақыйасының көмеш айы йалт-йолт йалтырар… [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, автор укучысына эндәшеп, үз исеменнән сөйләгән вакытта хикәяләү, хәзерге заманны белдерә торган *-а* кушымчалы I зат күплек сандагы

фигыльләр, хәзерге заманны белдерә торган вазифасы белән *-р* формалы фигыль һәм, Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» сәяхәтнамәсендә (1845) бер-ике мәртәбә күренеп үткән, К. Насыйриның кыйссаларында кулланылмаган, *-йур* кушымчалы фигыльләрнең берсе икенчесен алмаштырып файдаланылуы күзәтелә. *-йур* һәм *-р* формалы фигыльләр сөйләү моментында актуаль булган эш-хәлләрне белдерә: Атны сарай астында җирләштергән заманда менланың күзенә гүзәл бер күренеш раст кәлде: йорт буйынча бақчадан арт ханәйә бер қыз кәчәйүр, ...өстендәге йонныкы күк камзулы нәзек wә зифа буйына йахшы йакышыр… [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48], ... мәктүбне йазып, туташымыз әкертен атлап бақчайа мәзкүр қазық йанына чықайур [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 37] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, *-йур* һәм *-р* формасының III заты сөйләү моментында актуаль булган эш-хәлләрне белдерә. Яисә һәр өч формалы фигыль дә кабатлаулы, гадәти эш-хәлләрне белдерә торган мәгънәсе белән кулланыла: ...ахырынадик бәнди бөйлә уқыйур, ...бән улайым, сез улыңыз бер фәқыйрь күрсәк, җанымыз ағырып, қайғы хасил булыр... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 48]; ...шөйлә вақытларда ғарәбәилә чықсаң, көпчәк бәғзан қара кереп әйләнмәйүр, чана иләкитсәң, қарсыз йирләрдән кәчмәк лазем килә... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 49] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, хикәяләү барышында, *-йур, -р, -адыр* кушымчалы фигыльләр автор исеменнән I зат күплек санда һәм, асылда, берлек сандагы III заты кулланыла.

Кара-каршы сөйләшү бара торган өзекләрдә, сөйләү барышында актуаль мәгънәсе белән *-а* формалы фигыльнең I һәм II затлары файдаланыла, еш кына, сорауны белдерүче *-мы/-му* кисәкчәсе ала: хуш ула, пәк чәй wақытында йахшылық сағынып кәләсез, ...йегерме бишлек алышдырырмусыз, ...алышдырырмыз, [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 52]; ...Қурықма җаным,үзем кәләмән, ...қурқамән ки белмәсенләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 71]. Бу очракта күплек саны берничә кеше исеменнән сөйләнгәнлекне белдерә.

Аерым очракларда, I зат күплек сан тулы һәм кыска, II зат тулы зат кушымчасы алган хәлдә кулланыла. *-йур, -р* формалы фигыльләрнең юклык саны да еш кабатлана: сезә аwыл қызы йақышмаз... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 52]; ...әмма хәбес иделмәсенә сезең сәбәбче улдыңызы без һич инанмайурыз [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 15]; .... Бақың, бақың, йаман эшене үзе дә инкяр итмәйүр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 16] һ.б. Диалогик сөйләмдә, *-а* формалы

фигыльнең II заты да еш очрый: тапың чәй wақытында йахшылық сағыныб кәләсез [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 12]; ...сез бәнем әхлякеми wә табиғатеми белмәйсез [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 26]; Ай уғылым, нә сөйләрсән сән, әлбәттә, тәсбих wә чалмалы кеше изге кеше буладыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 49]. Бу әдиптә юклык формасы да тулы кушымча белән бирелә: ...бән сәне тиз йибәрмимән, җаным [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 38]; Үзең белерсән, балақай, хәзердәге йәшьләр белән сөйләб булмай [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 52]. *-а* формасының III заты да, аның I һәм II затлары кебек үк, диалогик сөйләмдә ешрак кулланыла: ...аwылымызда сөйлиләр ки [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 15]; ...менла: нинди ноқсанийат табалар [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 22] һ.б.

*-адыр* формалы фигыльләр, нигездә, даими кабатлана торган эш-гамәлләрне белдерә торган мәгънәсе белән файдаланыла, әмма авторның үз сөйләмендә төрле мәгънә төсмерләре белән баетылырга мөмкин: ...ғалим инсан ғйбәтләрдән қачадыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 13] җөмләсендә ул гадәти, даими хәзерге заманны белдерә; ...морадына наил ула, Хәнифәйе аладыр [Акъегет, 1886, б. 53] дигәндә, авторның ирониясе чагыла һ.б. *-а* формалы фигыльләр белән дә чиратлашу да күзәтелә: анда самовар төзәтәләр, монда лампа төзәтәләр, ...башны ағырталар [Акъегет, 1886, б. 45] һ.б. Бу очракта *икән*, *имеш* ярдәмлекләре белән килеп, хис-кичерешләр тасвир ителә: Нийә Алла бөйлә җәмиләләр йарата икән [Акъегет, 1886, б. 9]. Аңлашылганча, диалогик сөйләмдә, *-а* кушымчалы фигыльнең ешрак кабатлануы күренә, ләкин автор сөйләмендә дә, персонажлар сөйләмендә дә хәзерге заман мәгънәсе *-р, -йур* формалы фигыльләр белән эзлеклерәк тәкъбир ителә.

*-р* формасы, хәзерге заманны белдерүе белән бергә, тагын киләчәк заман мәгънәсе белән дә актив файдаланыла: ...бер байғуш күрсәк, җанымыз ағырып қайғы хасил улыр [Акъегет, 1886, б. 5]; ...сезә тиз вирерләр [Акъегет, 1886, б. 13], ...йарен син аны мөлзәм итәрсән [Акъегет, 1886, б. 14] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, әлеге әсәрдә *-р* формалы фигыльнең I заты, башлыча, диалогик сөйләмдә, тулы зат кушымчасы алганда, сөйләү моментыннан соң башкарылачак эшләрне билгеле бер дәрәҗәдәге катгыйлык белән белдерә, шул ук форма кыска зат кушымчасы алганда, киләчәк заманның мәгънәсе киңәйтелгән хәзерге заманга якыная, II заттагы фигыльләрдә дә шул ук мәгънә синтезы сизелә:

Кил, йөрәк бәғрем, вир җаwаб, бәңа мәхәббәт идерме сән [Акъегет, 1886, б. 28]. Бақ, қызым, өч көндән соң қайда эстәрсән, анда вар, бу эшләр ярамаз [Акъегет, 1886, б. 59] һ.б.

II һәм III заттагы *-р* формалы фигыльнең юклыгы, К. Насыйри һәм Г. Фәезханов әсәрләрендәгечә *-мас/-мәс* рәвешендә түгел, *-мәз, -маз* кушымчасы белән бирелә: ...ул изек үгрәтмәз, туғрыдан-туғры сүрә уқытыр [Акъегет, 1886, б. 3]; Безем менлалара ағыз ачмаға да вирмәз [Акъегет, 1886, б. 45]; Сезә тиз вирерләр, йахшы ғына сорамаға да өлгермәзсез [Акъегет, 1886, б. 13] һ.б. Шулай итеп, *-р* формалы фигыльнең юклык кушымчасындагы яңгырау һәм саңгырау тартыкның чиратлашуы һәм аның махсус сайланып кулланылуы функциональ-стилистик вариантлылык хасил итә дип әйтә алабыз. I зат фигыльләре юклыкта *-ма* күрсәткече ала: Бу йулы зәхмәтдән сайсақ, һичбер эшә йарамамыз [Акъегет, 1886, б. 8]; Бөйлә улса, бер-беремездән айырылмамыз [Акъегет, 1886, б. 41]. Сөйләү моментында актуаль булган эш-хәлләрнең юклыгы *-май* кушымчасы белән дә бирелә: ...йөрәк бәғрем баламдан айырдын, қандадыр, белмәймез [Акъегет, 1886, б. 60]; ...Анчақ белмәймән, ни өчен икән шатсән [Акъегет, 1886, б. 65] һ.б. *-йур* кушымчалы фигыльнең юклыгындагы *-ма* күрсәткечендә әлиф (ا) тә, фәтха хәрәкәсе дә язылмый, мим (م) графемасы белән генә бирелә: инанмайурыз, эстәмәйүрем, белмәйүрем [Акъегет, 1886, б. 15, 17, 37] һ.б.

Кыска зат кушымчалары алдында да юклык төшенчәсе шул ук формада килә: бирмиез, итмиез [Акъегет, 1886, б. 6] һ.б.

Сорау кисәкчәсе зат кушымчаларыннан алда куела: йикерме бишлек алышдырырмусыз (12), белермүсән, бүген-иртәгә эшне тәмам итәчәкләр (39), ғыйшықыма қаршы мәхәббәтеңне вирермесән [Акъегет, 1886, б. 12, 24, 39] һ.б.

Гомумтюркологик планда язылган хезмәтләрдә *-й* графемасының *-р* күрсәткече алдында тора торган сузык авазны саклау өчен барлыкка килүе [СИГТЯ, 1988, с. 407] һәм хәзерге вакытта әлеге күрсәткечнең угыз телләрен тәшкил итә торган төрек, азәрбайҗан, төрекмән, өлешчә, гагауз телләрендә генә кулланылышта булуы ассызыклана [Юлдашев, 1965, б. 140]. Димәк, *-йур* формасының кулланылышы өйрәнелә торган чорда язылган текстларның угыз-төрек теленә якынлыгын күрсәтә торган бер фактор булып санала ала. Р. Мирхәев әлеге формаларны татар әдәби теле һәм төрек әдәби теле мөнәсәбәтенә куеп анализлый [Мирхәев, 2007, б. 64].

Татар прозасының икенче төрендә иҗат итүче З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәриминең төрле жанр-стильдә язылган текстларында *-а, -йур, -р* фигыльләрен куллану, асылда, «Хисаметдин менла» әсәрендәге юнәлештә бара, әмма һәр авторда үзенчелекләр дә күзәтелә.

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887) романы авторның үз исеменнән *-а* кушымчалы фигыльнең I зат күплек саны белән башлана: Хикәйәмез ғаҗаиб гүзәл хикәйәдер. Хикәйәмези йахшы аңлатмақ өчен, әүwәлән вөқуғасы нә йирдә wә нә wақытда улдығыны йазамыз. Диалогик сөйләмдә *-а* формалы фигыльнең хәзерге заманны белдереп куллануы дәвам итә: – нә қарыйсыз, на улмыш? ...следовательне көтәләр, ...кәләләр, кәләләр..., ...тәфтишчеләрнең чығуына мөнтазир булып торалар... [Бигиев, 1991, б. 221]; Беләмен, бик яхшы беләмен, – дәйү җавап вирде Ғабдуллин [Бигиев, 1991, б. 221] һ.б. Хикәяләүне *-адыр* формалы III зат киңәйтелгән хәзерге заман формасы дәвам итә: ...җәмәғать арасында күп төрле сүзләр сөйләнәдер, ...мәқтүлә булуwыны уқыйдыр... [Бигиев, 1991, б. 221]; ...бу хатын нә wақытдан бирле сезнең нумиреңездә торадыр [Бигиев, 1991, б. 222] һ.б. *-йур* формасы да шушы ук мәгънәсе белән кулланыла: ...чәй эчәйүр, ...керергә эстәйүр [Бигиев, 1991, б. 224] һ.б., билгеле үткән заман фигыльләре ешрак файдаланыла: ...байтақ чәй эчеп сөйләшеп ултырдық [Бигиев, 1991, б. 224] һ.б

«Гөнаһе кәбаир» романы да шулай ук башлана: ...Ғабделғафурның кем wә ниндәләйен адәм улдығыны бәйән идәмез, ...зикер қыйламыз, ...ишарәт идәмез [Бигиев, 1991, б. 254]. Диалогик сөйләмдә: ...Менә уғлымызны Қазанға мәдрәсәгә уқырға йибәрәмез, дәйү уғылы Ғабделғафурға қарады [Бигиев, 1991, б. 255]; ...Нә wақыт, тизмү озатасыз? [Бигиев, 1991, б. 256]. Мисаллардан күренгәнчә, *-а* кушымчалы хәзерге заман хикәя фигыльнең I һәм II затлары сөйләмдә актуаль булган мәгънәсе белән файдаланыла. *-а* формалы фигыльнең III заты гадәти, кабатлаулы мәгънәсе белән кулланыла: ...Менә безем аwылдан... күп шәһәрләргә кидәләр, ...биш wақыт намазый мәсҗедә кәлеп, җәмағатьлә әда қыйлалар, ...йахшы, әдәбле wә инсафлы улып қайталар [Бигиев, 1991, б. 255]. Хикәяләү барышында, үткән заманнар белән берлектә, *-адыр* формасы файдаланыла: ...«гөнаһе кәбаир»ләр дә йеңел wә күб буладыр, ...түгел арақы эчәргә, чәйне дә ул wақытда бик аз кешеләр беләдер иде [Бигиев, 1991, б. 256] һ.б.

З. Бигиевнең бу әсәрләрендә хәзерге заманның гадәти, кабатлаулы мәгънәсе, *-а* формалы фигыль белән генә түгел, *-р (-йур)* кушымчалы фигыльләр белән дә бирелә, әмма алар сирәгрәк кулланыла. «Өлүф,

яки Гүзәл кыз Хәдичә»дә: ...үз-үзенә сөйләшәйүр [Бигиев, 1991, б. 224]; ...һәркемнең хәле бөйләдер, күзләремез күр-суқыр улдықындан күрмәйүрез [Бигиев, 1991, б. 234]; ...Сез ғазизләремезә бер-ике сәтьрә мәктүб йазмаға җөрәәт идәйүрмен [Бигиев, 1991, б. 235] һ.б.

«Гөнаһы кәбаир»да *-р, -йур* кушымчалы фигыль гадәти, кабатлаулы хәзерге заманны белдерә: ...йирләрә тиҗарәт өчен кидәйүрләр [Бигиев, 1991, б. 254], сөйләү вакытында актуаль булган хәлләрне белдерә: Шимди... биш кемсәнә мулла өйендә чәй эчәйүрләр [Бигиев, 1991, б. 255]; Шимди исә... Аллаһ сақласын, арақы өчен җанын фида қыйлыр, қарендәшен үлтерер, атасын қыйнар [Бигиев, 1991, б. 256].

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» (1890) әсәрендә I затның юклыгында кыска һәм тулы кушымчалар чиратлаша: Белмим, баланың атасыны бер-ике ай миқдар улды, күргәнем дә йук, белмим [Бигиев, 1890, б. 21]; Ул җәрәхәтнең нәдән улдыйғыны йақыйнә белмимән [Бигиев, 1890, б. 26]; Мән бу эшләрне һич тә белмимән, ...бер дә белмимән [Бигиев, 1890, б. 34]. Бу әсәрдә I зат берлек саны барлыкта тулы кушымча ала: ...сәламәтләнеб буламән [Бигиев, 1890, б. 17]; ...хатынлара шулай йәрдәм кыйламән [Бигиев, 1890, б. 20]; Яғқуб Ғалийевне бик йахшы беләмен [Бигиев, 1890, б. 22].

З. Бигиевнең сәнгатьле проза әсәрләрендә *-р* формалы фигыль, күпчелек очракта, киләчәк заман мәгънәсе белән кулланыла. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә: ...Муса әфәнде катыйль булса, әлбәттә, Муса әфәндене хәбес қыйлырлар [Бигиев, 1991, б. 226]; Иртәгә өйлә намазындан соң ике сәғатьдә кәлүр, сәламәт булсақ, иртәгә барып қарармыз, ...нә мәслихәт қыйлыр, шулай қыйлырмыз [Бигиев, 1991, б. 227] һ.б.

«Гөнаһе кәбаир»дә: Сәламәт булса, кәләсе җомға намазын Қазанда қыйлыр [Бигиев, 1991, б. 256]; ...Әйдә кантурайа бойыр, хәзер хисаб-счетлар вирермен [Бигиев, 1991, б. 260]. Әгәр дә бу эшләремездин кемсә хәбәрдар улмаса, соңра, йахшы туғры кәлгән wақытларда, күрешә торырмыз [Бигиев, 1991, б. 262] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, *-р* формалы киләчәк заман, нигездә, үзенең парадигматик мәгънәсе белән сөйләү моментыннан соң ук башкарылачак эш-хәлләрне белдерә, күп очракта вакыты төгәл итеп күрсәтелә (иртәгә сәгать икедә, бүген сәгать унбердә, сәгать алтыда һ.б.), тулы зат кушымчалары белән кулланыла. Шулай итеп, *-р* һәм *-а* формалы фигыльләрнең чәчмә әсәрләрдә кулланылуын тикшерү барышында, З. Бигиев романнарында кабатлану ешлыгына нигезләнеп, беренче

мәртәбә анализны *-а, -адыр* формалы фигыльдән башларга мөмкин булуы, *-р* формасының киләчәк заманны белдерү нигезенең тагын да ныгый баруы, шуның белән бергә, бу формалы фигыльләрне, шарт-нәтиҗә җөмлә мөнәсәбәтеннән шартлы-теләк дип аңлатырга мөмкин булуы да күренә.

Авторның «Мавәраэннаһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» (1908) сәяхәтнамәсендә хикәяләү барышы *-ды, -мыш, -р иде* формалы фигыльләр белән алып барылса да, өч заты һәм мәгънәләре белән, барлыкта һәм юклыкта *-р, -йур* формалы хәзерге заман фигыльләре дә эзлекле кулланыла. III зат кабатлаулы, гадәти мәгънәсе белән: Вабур хәрәкәтендә дәwам идәйүр [Бигиев, 1991, б. 289]; ...биш-ун парә куәтилә орада нөфүс тәзкирәсе нәсыл исә дә булуйурлар [Бигиев, 1991, б. 294]; ...Волга нәһрилә нәқәл улыныр малларың йөкләрең һәммәсе Қалач васитасыйлә тыйш диңгезләрә дигәр урынларә күндерелер, ...бер тарафдан бер тарафә нәқәл улыныр имеш [Бигиев, 1991, б. 295].

II зат сөйләү моментында актуаль мәгънәсе белән: Нәрәдән нәрәйә кидәрсез, әфәндем [Бигиев, 1991, б. 296] һ.б.

I зат кабатлаулы, гадәти мәгънәсе белән: ...Мәдәнийәт тарихына нәзар идәр исәк, Русийәне ғайәть соң сәтырларда күрийүрез [Бигиев, 1991, б. 296]; ...Казан вилайате мөселманларыны пәк йахшы белерүм [Бигиев, 1991, б. 296]; ...Ғыйлем wә әхуале дөньйайе, инсанларның хәқыйқатьләрене сездән зийәдә һәм туғры белүрем. ...Иштә бән шимди шу сәғать сезә у wақыйғайе бәйан, хикәйә идәрем [Бигиев, 1991, б. 297] һ.б. Әдипнең сәяхәтнамәсендә I затның юклыгы *-мәм* кушымчасы белән язылa: Белмәм, нәсыл, ...намус сахибләре улдылар [Бигиев, 1991, б. 299]; ...бән қаләмлә тәмамән тәғриф wә тасвир идәмәм белмәм... [Бигиев, 1991, б. 317] һ.б.

Сәяхәтнамә текстында *-р* формалы фигыль хәзерге заман мәгънәсендә дә, киләчәк заман мәгънәсендә дә, гадәттә, зат кушымчасының кыска варианты белән файдаланыла: Инша аллаһ, һәр берењези сәламәтлекдә мәқсудыңыза исаль идәрем [Бигиев, 1991, б. 289]; Мәдәнийәт тарихына нәзар идәр исәк, Русийәне ғайәт соң сәтырларда күрийүрез [Бигиев, 1991, б. 296] һ.б.

Шулай итеп, *-р* формалы фигыль З. Бигиевнең сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә тулы зат кушымчасы белән эзлекле рәвештә киләчәк заман мағънәсендә, ә сәяхәтнамә текстында, кыска зат кушымчасы белән һәм хәзерге заман, һәм киләчәк заман мәгънәсендә кулланыла. Бу үзенчәлек Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә дәвам ителә.

Әмма бу әдипнең сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә *-а* формалы фигыль активлашу сәбәпле, *-р* формасының хәзерге заман мәгънәсендә кулланылуы сирәгәя. «Салих бабайның өйләнүе» (1898) хикәясендә һәр өч зат белән дә *-а* формалы фигыль кабатлана һәм, асылда, гадәти, даими мәгънәсе белән файдаланыла: ...тар табиғатьле wә холықсыз қайната, қайнаналардан күп әза, җәфа күрәләр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 220]; ...ни өчен қайғырасың, әбине сағынасыңмы [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 221]; ...ачысыны бераз татыйбыз, мәктәптә имтихан дигән нәрсә бар, шуның өстенә тоз сипкән торма тәмләре килә, икенче йылға қадәр тамағымыздан ачысы китми [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 222]. *-адыр* формасы белән чиратлаша: бөтен өс-башны йәки бит-күзне тутырадыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 222] һ.б. Бу хикәядә *-р* формалы фигыль хәзерге-киләчәк мәгънәсендә бер-ике мәртәбә кулланыла: Бик хуш булыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 223]; Уналты, унҗиде йәшенә җитеп җиләк кебек пешкән қызыл йаңақлы, саф күзле аwыл қызларының дәтафәт wә дилбәрлекне тәғриф итмәк кемнең қулыннан килер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 225]. Ләкин бу әсәрдә әлегә кадәр сирәк күзәтелгән *-макда, -учан, -а торган* формалары эзлекле файдаланыла башлый. «Җиһангир мәхдүмнең ауыл мәктәбендә укуы» (1898) хикәясендә: *-а* формалы фигыль сөйләү моментында актуаль булган мәгънәсе белән: ...менә бүген әлеп, би уқыйдыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 230], ...самоварның крантыны борып қуйғаннар, суы ағып беткән, чаж-чож эреп утыра, ...әлиф йатығыз, әлиф йатығыз! дип қычқырып тора [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 236] һ.б.

*-р* формалы фигыль киләчәк заман мәгънәсе белән: ...исән-сау булса, бераздан иман иҗеге башлар. Йазға таба бәлки һәфтийәк иҗегенә дә төшәр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 230]; ...Иртәгә мәсҗеддән чығуға мин хәзрәтне чәйгә алып килермен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 240].

«Бер шәкерт илә бер студент» (1899) хикәясендә *-а* кушымчалы хәзерге заман фигыле I зат берлектә тулы кушымча белән сөйләү моментында актуаль мәгънәне белдерә: ...Бу ни эшли икән дип торамын. ...Һәрбер хәрәкәтләренә диққать итеп торамын [Кәрими, 1996, б. 38]; ...мин сезнең телне дә беләмен [Кәрими, 1996, б. 39] һ.б. Шул ук мәгънә кыска аффикс белән дә күрсәтелә: Тирә-йақны сәйер итеп барам [Кәрими, 1996, б. 37]; ...һәдия булдыгы өчен бу китапны қабул итеп алам. ...Бу сүзне қабул итә алмыйм [Кәрими, 1996, б. 54] һ.б. Шул ук

мәгънә II зат берлек һәм күплектә тулы кушымча белән белдерелә: Сез кем буласыз? ...Ник соң син мондайын кийемнәр кийәсең? [Кәрими, 1996, б. 36]; ...Қайа барасың? Ник барасың, хәзер қайдан киләсең [Кәрими, 1996, б. 40] һ.б. Шул ук актуаль мәгънә III зат берлек сан белән белдерелә: ...қайсы утырған гәзитә уқый, қайсы қарап бара, қайсы йөри [Кәрими, 1996, б. 37], III зат күплек сан актуаль мәгънәсе белән бирелә: ...телсез кешеләр кебек, тилмереп wә исләре китеп русның күзенә қарыйлар... [Кәрими, 1996, б. 39] һ.б. Шул ук форма гадәти, кабатлаулы мәгънәсе белән кулланыла: Каникул дип тәғтыйл wақытына әйтәләр. Безнең мәктәпләрдә һәр йыл ике-өч ай тәғтыйль йасап, шәкертләргә истирахәт итәргә изен бирәләр, ...Әллисанани шәрқыйә мәктәбендә барлығы өч-дүрт йыл уқыйлар [Кәрими, 1996, б. 42]. Шул ук мәгънәне бирү өчен *-адыр* формасы да кулланыла: ...Барысы да ахырзаман ғаләмәтләре! Дөньйаға кирәкмәс нәрсәләр туладыр [Кәрими, 1996, б. 52]; ...Гәрчә әдәп wә тәрбийә шулай иқтиза итәдер, олуғ кешеләр йанында күп сөйләргә тиеш түгел... [Кәрими, 1996, б. 53] һ.б.

Бу әсәрдә *-р* формалы фигыльнең I зат берлек саны кыска кушымча белән киләчәк заман мәгънәсен белдерә: Андан бонларны да сорашып, кем булғаннарын белерем дә, соңыңдан күрешермен дидем [Кәрими, 1996, б. 32]; Кем уқытырса, бәддоға итәрем [Кәрими, 1996, б. 48]. Госманлы төрекчәсене белермүсиңез? [Кәрими, 1996, б. 39] дигән сорау җөмләдә II зат күплектә, III зат берлек һәм күплек формасының кабатлаулы гадәти хәзерге-киләчәк заманны белдереп кулланыла: ...Бер кеше бер тел белсә, бер инсан саналыр, өч тел белсә, өч инсан саналыр. Чөнки өч кешенең күрәчәге эшне йалғыз башына күрер. ...Әгәр төрле телләр белгән кешеләр булмаса, аларны безнең рус милләтенә кем тәрҗемә итеп бирер? Алар ничек хәбәрдар булырлар? [Кәрими, 1996, б. 44]. Соңгы ике җөмләнең киләчәк заманны белдерүе аңлашыла. Түбәндәге җөмләләрдә дә *-р* формасы киләчәк заман мәгънәсе белән кулланыла: ...Бездән илле йыл, йөз йыл соңра булган кешеләргә бер йәдкяр булсын. Алар бу китапны уқып, үзләренең бабалары эчендә ниқадәр фикерсез, мөтәғассыйб адәмнәр булғанын күрерләр. Инсаннарны тәрәққый иттермәк ниқадәр мөшкил wә аwыр булдығын истихраҗ итәрләр. Бәлки комедия ясап, театрларда уйнарлар [Кәрими, 1996, б. 54] һ.б. Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, *-а* формалы фигыль берничә мәгънәсе белән хәзерге заманны, *-р* формасының хәзерге заманны белдерү мәгънәсе шактый чикләнгән хәлдә, асылда, киләчәк заманны белдерә торган мәгънәсе белән кулланыла.

«Морза кызы Фатыйма» (1901) әсәрендә *-а* формалы фигыль I зат берлектә, тулы кушымчасы белән хәзерге заманның гадәти, кабатлана торган мәгънәсе белән кулланыла: ...килгән қадерле қунақларның күңеленә хушлық бирсен дип тәрбийә итәмен... [Кәрими, 1996, б. 84]; Сөйенечемнән ғақылымны ғаиб итмәсәм йарар иде дийә қурқамын [Кәрими, 1996, б. 100]. III зат берлек һәм күплектәге фигыльләр дә шул ук мәгънәдә файдаланыла: ...Қырымның Қара диңгез буйлары фәүқыльғадә ләтыйф wә гүзәлдер, бер тарафта иге-чиге күренми торған Қара диңгез сулары йомшақ қына искән җил илә тибрәнеп, моңлы күңелләрне қузғатып тора. Икенче тарафта түбәләре күккә кадәр күтәрелгән ташлы таглар, баласын саклый торган арысланнар кебек, үзләренең итәкләрендә бина ителмеш аwылларға wә дачаларға ғазәмәт wә дәһшәт илә нәзарәт итеп торалар... [Кәрими, 1996, б. 80] һ.б.

*-а* кушымчалы хәзерге заман хикәя фигыльнең даими, гадәти, кабатлаулы эш-хәлләрне белдерә торган мәгънәсе белән кулланыла торган җөмләләрдә шулай ук әлеге мәгънәне көчәйтеп, тәгаенләп җибәрә торган *һәркайчан*, *һәрвакыт*, *һәмишә*, *мәгълүмдер ки* һ.б. кебек лексик чаралар да файдаланыла, әлеге сүзләр булмаганда да фигыльнең нинди мәгънәсе белән кулланылуы яхшы аңлашыла. Бу төрдәге мисалларны Ф. Кәриминең башка әсәрләреннән эзлекле итеп китерергә һәм түбәндәгечә нәтиҗә ясарга мөмкин: Ф. Кәрими үзенең сәнгатьле прозасында аңа кадәр бер-ике җөмлә белән генә чагыла башлаган һәм татар стилистикасында уртак сөйләм дип атала торган (Курбатов, 1956) хикәяләү алымын киңәйтә һәм нәкъ менә шушы сөйләмдә *-а* кушымчалы фигыльләр сөйләү моментында башкарыла торган мәгънәсе белән ешрак кулланыла, бу очракта җөмләләр *менә*, *хәзер*, *күреп торасыз* кебек лексик чаралар белән дә көчәйтелә. III затта исә *-а* һәм *-адыр* формалары үзара синоним парлар буларак алмаштырып кулланыла.

Әдипнең Кырымда булган хәлләрне үз чоры татар әдәби теленең җәдиди госманлы вариантына якын итеп язылган «Морза кызы Фатыйма» әсәрендә *-р* формалы фигыль үзенең хәзерге заман мәгънәсе белән дә, киләчәк заман мәгънәсе белән дә, башка хикәяләренә караганда, берникадәр дәрәҗәдә күбрәк кабатлана: ...Белерем ки, сән дә бәнем өчен күп зәхмәтләр күрдең [Кәрими, 1996, б. 95]; ...Йарар, соңыннан қарармыз. ...Бән сәне кальбемнең бер җөзьә wә күземнең қарасы кеби сөйәрем. ...кәндемнең нә қадәр бәдбәхет wә талиғсыз бер адәм улдығымны дөшендекем wақыт бәсбөтен мәэйүс улыйурым [Кәрими, 1996, б. 96]; ...боңа тәшәккерләр идәрем, ...өмид идәрем

[Кәрими, 1996, б. 98], шул ук вакытта *-йур* формалы фигыльнең файдаланылуы күзәтелә.

Әмма әлеге форма авторның сәяхәтнамәләрендә активлаша. Әдипнең «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә *-р (-йур)* формалы фигыльнең һәр өч заты да эзлекле булып кулланыла: ...Шакир әфәнде кәнде ғаиләсе илә күрешәйүр – видаг идәйүр. Бән дәхи кәнде рафиқаларым булған назыйрь wә мөғаллимнәр илә күрешәйүрем. ...Калебләр тулайур, күзләр йәшләнәйүр. ...Өч айлық сәйәхәткә кителәйүр [Кәрими, 1996, б. 152]. I һәм II зат фигыльләр, нигездә, диалогик сөйләмдә активрак: – Йуқ, хәзрәт, бән – иске йахуд йаңа ысул димәйүрем, бәлки мәктәбеңездәге уқулар бераз низам wә тәртип илә улырса wә шәкертләр дә дәха зийәдә истифадә идәрләрсә, дәха муафиқ улыр иде дийәйүрем [Кәрими, 1996, б. 176]; ...Сәбәбене кәндемез дә белмәйүрбез, әфәндем [Кәрими, 1996, б. 183] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, *-йур* формалы фигыль I зат берлектә кыска *(-м),* күплектә кыска *(-з)* һәм тулы *(-без)* кушымчалары белән, нигездә, сөйләү моментында актуаль булган эш-хәлләрне белдерү өчен файдаланыла, II зат сирәк кулланыла, *-сыңыз* кушымчасы ала: ...Нәрәйә китәйүрсеңез? Ничен китәйүрсеңез? Wә нә wақыт китәчәксеңез [Кәрими, 1996, б. 184]; ...ул да французча буларақ: «Қаһwә йәхуд чәй эчмәк эстәмәйүрмесеңез? Ахшам йимәке бойурмайумысыңыз?» – диде [Кәрими, 1996, б. 200] һ.б.

*-йур* кушымчалы фигыльнең III заты, сөйләү моментында актуаль булган мәгънәне белдерү белән бергә, даими, гадәти, кабатлаулы эш-хәлләрне дә аңлата: Бәғзесе көлер, wә бәғзесе аһ идәйүр-йығлайур [Кәрими, 1996, б. 156]. Безем ғоламәнең бәғзесе зан идәйүрләр ки, ...йаңа хикмәтләрне wә йаңа фәлсәфәләрне бақмаға хаҗәт йукдыр [Кәрими, 1996, б. 157] һ.б.

Ф. Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе» текстында *-йурды* һәм *-йурмыш* формалары еш кабатлана. Әлеге күрсәткечләрнең *-йур иде* һәм *-йур имеш* аналитик формаларыннан кыскарган булулары мәгълүм [Юлдашев, 1965, б. 140], билгеле бер дәрәҗәдә алар параллель дә кулланыла: Шакир әфәнде, кәнде алтын мәғдәннәрендә эшләтмәк өчен, локомобиль (пар машинасы) wә саир аләтләр алмақ эстәйүр иде [Кәрими, 1996, б. 166]; ...мөштәри тарафыннан тәғайен ителгән wақытта машинаның хәзер булмасы өчен тәнбиһ идәйүрләр имеш [Кәрими, 1996, б. 166] һ.б. Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, *-йурды* һәм *-йур иде* формаларының мәгънәләрендә билгеле бер аерымлану

сиземләнә: *-йурды* сөйләү вакытында актуаль булган, тәмамланган, кабатланмаган эш-хәлне, *-йур иде* тәмамланмаган эш-хәлләрне белдерә. *-йүрмеш* формасындагы *имеш* ярдәмлеге, хәзерге әдәби телдәге *икән* мәгънәсен, ягъни хәбәр составында килеп, фикерне раслау, ачыклау төсмерен бирә.

Ф. Кәриминең «Кырымга сәяхәт» (1904) юлъязмасында да *-р (-йур)* формалы фигыльләрнең кулланылышы, асылда, «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндәге кебек ук (тик бу тексттагы диалогларда *-а* формасы ешрак кабатлана): – Сез хәзер қайда барасыз? – Бағчасарайға варамыз [Кәрими, 1996, б. 319]. Ихтирам күрсәтергә кирәк булганда, *-йур* формасы сайлана: Әвәт, барышня, без улайурбыз, йуқса бер әмереңезме вар [Кәрими, 1996, б. 322]; Без Қоръәнемезне аңламайурбыз, чөнки Қоръәнемез ғарәпчәдер, без ул лисанны белмәйүрбез [Кәрими, 1996, б. 325]. «Тәрҗеман» идарәсенә язылган тәшәккер намә текстында да, әлбәттә, *-йур* кушымчалы фигыльләр кулланыла: «Тәрҗеман» гәзитәсенең 20 сәнәлек дәwамында wә аның мөхәррире булынған сез зател ғалийел қадирның 20 сәнәлек хезмәт миллийә wә сәғый мәғариф пәрwәранәсенә тәшәккер доғасы мәҗлесендә булынайурбыз [Кәрими, 1996, б. 380] һ.б. Ф. Кәриминең бу сәяхәтнамәсендә, беренчесе белән чагыштырганда, *-рды, -рмыш* формалары сирәгрәк файдаланыла: Бонда йапылған айақ қаплары Қырымның һәр тарафына wә Кавказийәгә һәм сатылыйурмыш [Кәрими, 1996, б. 363] һ.б. Шулай итеп, Ф. Кәриминең сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә бер-ике мәртәбә кабатлана торган *-р (-йур)* формалы фигыльләр аның сәяхәтнамәләрендә эзлекле булып рәттән тезелеп бара һәм хәзерге заманның да, киләчәк заманның да төрле мәгънәләрендә кулланыла, шул нигездә барлык төрки халыклар да укый алырлык текст барлыкка килә, автор үзенең максатына ирешә.

Р. Фәхретдиннең фәнни мәкаләләрендәге кебек, «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1899) романында *-р* формалы хәзерге-киләчәк заман фигыле төрле мәгънәләләре белән кулланыла. Тормышта гомумкабул ителгән, бәхәссез хакыйкать булып саналган вакытка мөнәсәбәтсез эш-хәлләрне белдерә: Әдәпле – ул халық сәвәр; ғыйффәтле – ул Аллаһы Тәғалә сәвәр; сабырлы – ул үкенмәзсән; тәхәммелле – ул қартаймазсән. Һәр сүзне аңламақ ...кеби бер Камаләт һәрбер кемсәнәдә табылыр исә, ...җөмлә адәм баласы бер тигез улмыш улыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267]. Кабатлана торган, гадәти эш-хәлләрне белдерү мәгънәсе белән: Дустларның барлықлары ошбу кеби көнләрдә беленер. ...Дөньйада сәүдермәк йәки биздермәк, бозмақ бар вар

дия иғтиқат идүчеләрдә күрелгән йөрәксезлек буңа дөрест шаһид ула белер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 270] һ.б. *-р* формалы фигыль киләчәк заман мәгънәсе белән файдаланыла: ...иқрамыңызи шадланыб кабул идәмез, йахшы исемнәреңези мәмләкәтемезгә қадәр йөкләб китәрмез [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 275]; Алай исә хуш улыр, озын wақыт, күрешермез [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 280] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, *-р* формалы киләчәк заман фигыле фәкать тулы зат кушымчасы белән генә файдаланыла. *-а* формалы хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат берлектәге барлыгы да тулы кушымча ала: ...халән айырыламән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 270]; ...бән һәм хөлус калебем илә өмид идәмән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 286] һ.б.

Әдипнең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) романыңда *-а, -р, -йур, -адыр* формалы фигыльләр кулланыла. I зат күплектәге *-а* формасы авторның үз исеменнән хәбәр итүен белдерү өчен файдаланыла: Имде бу хатыннарны, хосусан яшь кызны күп мәртәбә зикер итмәк лазем улдыгы өчен, «Сәлимә туташ» дип язамыз [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 273]. Бер үк җөмләдә *-а* формасының хәзерге заманда, *-р* формасының киләчәк заманда кулланылуы күренә: ...икрамыңызи шатланып қабул идәмез, йахшы исемнәреңези мәмләкәтемезгә қадәр йөкләп кидәрмез , диде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 275] һ.б.

Шуның белән бергә, бу әсәрдә хикәяләү, үткән заман фигыльләре белән берлектә, *-р* формалы фигыльнең кабатлана торган, гадәти эш-хәлләрне белдерү мәгънәсе белән бара: Ирләрнең һиммәте урыннарындан тауларны күчерер, диерләр. Ләкин хатыннарның һиммәте бондан дәхи бәләндер. Зирә анларның һиммәтләре арсланнардан ғайрәтле ирләрне кәнде фәрманнары астында тотарлар. ...Ирләр һәрwақытта хатыннар теләгәнчә улырлар [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 314] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, *-йур* формалы фигыльләр сөйләү моментында актуаль булган хәлләрне белдерә. Кыска кушымча алган *-р* формасы да шушы ук мәгънәсе белән кулланыла: ...бәлки биш йөз йәки мең тәңкәлек сәнәд (вексель) бирер исәң, әлбәттә қабул итәрем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 342]; ...Мәзкүр балаға бәйлә бер алтын тәңкә бирдегең хәтереңдә йуқмы? Бирдем, бу кеби белерем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 352]. Шулай итеп, хәзерге заманны да, киләчәк заманны да белдерергә мөмкинлеге булган *-а* һәм *-р* күрсәткечле фигыльләр, һәр авторның максатына туры китерелеп, эзлекле рәвештә кулланыла, әмма традиция дәвам ителгән хәлдә, хәзерге

әдәби телдә урнашачак норма да тотрыклана бара. Бу мәсьәлә классик әдипләр иҗатында тагын да ачыграк чагылыш таба.

Татар прозасында хикәяләүнең өченче төрен башлап җибәрүче Г. Исхакыйның беренче хикәяләрендә *-р* формалы фигыльнең хәзерге заман мәгънәсендә кулланылуы дәвам ителәә. «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1899) әсәрендә: Фатыйма қайтып керер [Исхакый, 1998, б. 36]; ...Хәлим, тәһарәт алып, зийарәткә китәр [Исхакый, 1998, б. 37]; ...Хәлим шатланып Кәрим берлә күрешеп килер. ...Хәлим дә хәзрәт берлә, соңра мәсҗет қартлары берлә күрешеп чығып китәр. [Исхакый, 1998, б. 39] һ.б. Аңлашылганча, автор сөйләмендә *-р* формалы фигыльләрнең сөйләү моментында актуаль булган мәгънәсе белән кулланылуы күренә. Персонажының Раббыга шөкер кылуын тасвирлау өчен дә *-р* формалы фигыль I һәм II зат берлек һәм күплек санда актуаль мәгънәсендә кулланыла: Әй Раббем, сиңа ни дәрәҗәдә шөкерләр қылырға белмим, ...бән қолың. Әле эстәсәң – бирерсең, теләсәң – алырсың, бирсәң – тәшәккердә булырым, алсаң – сабыр қылырмын. ...Җәй фасылының үстердеге йәшел үләннәр, төрле сачәкләр, хуш-хуш исләр һәр қайусы миңа көлеп: «Хәлим, сине тәбрик идәрез», – диерләр [Исхакый, 1998, б. 36] һ.б.

Персонажларның кара-каршы сөйләшүе рәвешендә язылган урыннарда, мәгърифәтчеләрнең әсәрләрендәге кебек үк, шул ук мәгънәдә *-а* формалы фигыльләрнең I заты кабатлана: Мин белмим [Исхакый, 1998, б. 32]; ...мин чыгам [Исхакый, 1998, б. 36]; ...ун тәнкә генә үзем бирәм [Исхакый, 1998, б. 36]; ...сиңа ни дәрәҗәдә шөкерләр қылырға белмим [Исхакый, 1998, б. 36] һ.б. Фигыльләрнең күбесе кыска кушымча белән кулланылганга, персонажларның сөйләме гадәти җанлы сөйләмгә якыная. Иманлы, гыйлемле булу турында автор белән персонажның уртак сөйләме рәвешендәге өзекләрдә *-р* һәм *-а* формалы фигыльләр, тулы кушымча алып, бер үк мәгънәдә чиратлашып кулланыла: кийемнәрен кийәрмен, ...қаwағыйде ғарәбидән истифтах уқыймын, ...аңардан имтихан бирермен дә истиқмаль берлә дәрүсе шифаһийә уқыймын, ғарәпчә сөйләшергә өйрәнермен... [Исхакый, 1998, б. 37]. Әмма бу җөмләләрдә *-р* формалы фигыльнең киләчәк заман мәгънәсенә таба йөз тотуы аңлашыла: ...тарихы ислам уқырмын, җәғрәфия уқырмын, ...белермен, ...иманымны гүзәлләрмен, ...бөтен кешене белүемә ғаҗәпкә қалдырырмын [Исхакый, 1998, б. 37] һ.б.

Г. Исхакыйның башка хикәяләрендә дә *-р* формасының, хәзерге заманны белдерүенә караганда, тулы зат кушымчалары белән

билгесез киләчәк заман мәгънәсендә кулланылуы эзлекле күзәтелә. «Кәләпүшче кыз»да: Аннан ары кем булырмын? Хәлфә, безнең шикелле күп уқысаңыз, сез дә шулай йә мөдәррис, йә мөғаллим булып рәхәтләнеп торырсыз, дийә иде. Мин шулай булмайынча қалырмынмени [Исхакый, 1998, б. 53] һ.б. Әдипнең бу әсәрендә *-а* формалы фигыльнең дә киләчәк заман мәгънәсендә кулланылуы күзәтелә: Болай булғач, иргә дә бара алмый [Исхакый, 1998, б. 71]; Бармаса, ачқа үлә [Исхакый, 1998, б. 74]. Бу хәл әдипнең башка әсәрләрендә дә дәвам ителә. Мәсәлән, «Бай угылы»нда: Ул бозылып китсә, безнең дәүләт кенә йитәме соң [Исхакый, 1998, б. 125]. Бу әсәрдә, бер үк җөмләдә *-р* формалы киләчәк заман *-а* формалы киләчәк заман белән бергә килә: Уқытасыңыз килсә, үземезнең мәхдүмгә генә бирерсез, аның шәкертләре алай әллә нәрсә белмиләр, йуаш қына булалар. Ул үзе дә әллә нәрсәләр уқытмый, баруы-қайтуы үзеңез теләгәнчә булыр [Исхакый, 1998, б. 126]. Шулай итеп, Г. Исхакыйның беренче әсәрләрендә, *-р* һәм *-а* формалы фигыльләрнең һәм хәзерге, һәм киләчәк мәгънәне белдереп кулланылуы аңлашыла. Хикәяләү барышында функциональ-стилистик вариантлылык хасил итә, дип әйтә алабыз, чөнки традицияне ныграк саклап, рухи бөеклекне тасвир итү өчен, *-р* формалы, җанлы сөйләм итеп бирелә торган урыннарда *-а* формалы фигыльләр кулланыла, тулы һәм кыска кушымчалары да туры китерелеп сайлана.

Аңлашылганча, башка тел чаралары кебек үк, фигыль заманнарының кулланылышы да һәр аерым әсәрдә тасвирлана торган вакыйга-гамәлләрнең табигатенә, аларга карата автор мөнәсәбәтенең нинди булуына барып тоташа, һәр әсәрдә эстетик эчтәлекне алып килә торган сәнгати чаралар, шул әсәрдә күтәрелгән теманы һәм автор әйтергә теләгән идеяне укучыга төгәл итеп җиткерү максатына яраклашалар, һәр әсәрне аерып алып өйрәнергә, тел чараларын да аерып алып тикшерергә кирәк була. Мәгърифәтче әдипләрдән аермалы буларак, классик әдипләр үзләренең әсәрләрендә бара торган хәлләрне бер кеше карашыннан чыгып кына хикәяләми, әсәр «мин» исеменнән дә, III заттан да, яисә боларның үзара кушылып китүе белән барлыкка килгән уртак сөйләм белән дә алып барылырга мөмкин. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» дип исемләнгән беренче хикәясе I заттан хикәяләнә башлый, персонажларның кара-каршы сөйләшүе булып дәвам итеlә, «Кәләпүшче кыз», «Бай угылы» – III заттан, «Очрашу яки Гөлгыйзар», «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Зиндан», «Тормышму бу?» әсәрләре – I заттан, күп

кенә прозасы III заттан хикәяләнә. Әдәби әсәрдә бара торган вакыйганың кайсы заттан хикәяләнүе дә фигыль формаларының сайланышына, аларның кабатлану ешлыгына нык тәэсир итә. Әлеге тәэсирнең ни дәрәҗәдә булуы проза һәм драма жанрларын чагыштырып караганда тагын да ачыграк күренә.

Беренче драма әсәрләрендә *-р* формалы хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең кулланылышында, язма традиция белән сөйләмә нормаларның ничек итеп кушылуын күзәтергә мөмкин. Аңлашылганча, персонажлар сөйләмендә *-а* формалы фигыльнең I һәм II затлары файдаланыла. Г. Ильясиның «Бичара кыз» (1887) драмасында: ...Қарыйм, қарыйм болар мине икенче кешегә бирәләр. ...Шуңа күрә әйтәм, ...дип әйтәм. Йахшы, мин чығып торам. Шөкер бик исән йөрим. – Тукта әле, сиңа әйтәм, қара әле, рөхсәт итсәң, қызлар җыйар идек дип әйтәм. ...мин кызганам һ.б. Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» (1888) драмасында: Җанбайға барам дип йазған. Мин бер дә ышанмыйм [Халидов, 1888, б. 4]; ...мин бай балаларының шунысын йаратам... [Халидов, 1888, б. 7]; ...қолақ сөйенчелеккә йөз тәңкә бирәм [Халидов, 1888, б. 8]. «Морад Сәлимов» әсәрендә: ...белми дә торам. ...Мин Яғкуб байны бер дә қызғанмыймән, ...әйтәме соң фәлəнгә бармайым, фәлəнгә барам дип, ...мин қурқам һ.б.

Өйрәнелә торган чорда язылган текстларда *-а* кушымчалы хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат күплек саны, аның берлек санына караганда, һәр җәһәттән күбрәк эш башкара. Хәзерге әдәби телдән аермалы буларак, өч варианттагы зат кушымчасын *-з, -мыз, -быз* ала. Боларның берсе авторның максатына туры китерелеп, махсус сайланып кулланыла, димәк, функциональ-стилистик вариантлылык та хасил итә. Үз чоры татар әдәби теленең классик иске татар варианты белән язылган текстларда *-мыз,* аның госманлы теленә якынайтылып язылганнарында, *-мыз* аффиксы белән бергә, *-з* кушымчасы да файдаланыла, ә инде халыкның җанлы сөйләменә якынайтылганнарында *-быз* формасы өстенлек итә. Әлеге үзенчәлек II зат кушымчаларында да чагыла. «Рәдде бичара кыз»да: Биби әби әйтә: Җә инде, Сәлимә, йәшь wақытда хәзер аwырыйсың да, хәзер тереләсең [Халидов, 1888, б. 3]. Зат кушымчасы *-сән* булып түгел, ә җанлы сөйләмгә хас булганча, *-сың* булып языла башлый. Әлеге әсәрдә II зат берлек саны, теләк-хуплауны белдергән мәгънәсе белән кулланылганда, *-сән* кушымчасы белән бирелә: Мирза әйтә: Хуш киләсән, Биби әби [Халидов, 1888, б. 13] һ.б.

Авторның үз сүзләре итеп бирелгән ремаркаларда, сөйләү моментында актуаль булган эш-хәлләрне белдерү өчен, *-р* формасы кулланыла, шул ук мәгънә персонажлар сөйләмендә -а формасы белән бирелә. Мәсәлән, Г. Ильясиның «Бичара кыз» (1887) драмасында: (Бу wақытта Фатыйма керер). Сандуғачлар сайрый, ағачлар йафракка бөреләнә, нәфис хуш җилләр исәдер... Фатыйма. Қойаш батуымы, белмим... (дип, Фатыйма чығар)... [Татар әдәбияты, 1957, б. 555]; Фәрихә. Йуқ, қызым, аwырый торғансыңдыр ...туқта, Сәхибә абыстайны алдырыйм (дип чығып китәр). [Татар әдәбияты, 1957, б. 556] һ.б.Ремаркалардагы *-р* формасы сирәк кенә *-а (дыр)* формасы белән дә чиратлаша: Сәхибә. Чү,чү,чү... (дип, қызның башын тота да)... [Татар әдәбияты, 1957, б. 556]. Бу төрдәге чиратлашу вакыйга бара торган урынны тасвирлаганда да күренә: Сәхибә хәзерләп бирер. Маһитап кийем шкафыннан бер асыл күлмәк алып бирер. Сәхибә китәр [Татар әдәбияты, 1957, б. 557] һ.б.

Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» (1888) драмасында, актуаль мәгънәне белдерү өчен *-р* формасы файдаланылу дәвам ителсә дә, *-а* формасы активлаша: Пәрдә ачылыр. ...Сәлимә хатын идән себерә. Хәлимә иске күлмәк кигән. Шул күлмәгенең җыртығын җамап кроватьда утырған wақытда, Хәлимәнең инәсе сынар да (Халимә әйтә моңайып)... Инде ни хәл қылайым, эти дә тиз қайтмас инде... [Татар әдәбияты, 1957, б. 575]. Бу драмада персонажларның сүзгә керешүе, сөйли башлавы *-а* формасы белән бирелә: Сәлимә әйтә, Биби әби әйтә, Мәхүп әйтә. Мирза әйтә һ.б. Әмма аңлатмаларда *-р* формасы да саклана: ...Җә инде, Сәлимә, бу чақта приказчиклар байлардан бай була... (дип, аһ итеп эченнән уйлар: ...мин мең хәйлә берлә туйларын бозармын, дип сулап җибәрер) [Татар әдәбияты, 1957, б. 577]. *-а* формасы ешрак кабатлана: Хәлимә ағызларын йылмайтып сорый. ...Сәлимә әйтә: Туқта, атасы, ...Биби әби килде йаучы булып Хәлимәгә (дигәч, Хәлимә ағызын тотып ишектән чығып китә. ...Сәлимә Биби әбинең сүзләрен барын да Мирзаға әйтә) [Татар әдәбияты, 1957, б. 579] һ.б.

Ф. Халидинең «Морад Сәлимов» (1905) драмасында автор ремаркаларында актуаль заман фәкать *-р* формасы белән генә бирелә: Морад (ишектән керер, бүрекене һәм өстендәге кийемене салып чөйгә элер, кесәсеннән ақ йаулықны чығарып, борыныны сөртеп, аһ итеп сулап, бер урындыққа утырып, бераз уйлап торғач, башыны селкеп әйтер)... [Татар әдәбияты, 1957, б. 593] һ.б.

Әлеге ике драмадагы ремаркаларның бирелешен чагыштырып, мондый нәтиҗә ясарга мөмкин: автор гади кешеләрнең тормышын

сурәтләгәндә, үзенең сүзен дә аларча бирергә кирәк дип белә, ә зыялы персонажын тасвирлаганда югары стильне, ягъни традицион язма формаларны сакларга тырыша.

Ф. Халидинең «Саран, надан Теллә бай хикәяте» драмасында (1906) ремаркалар шактый сирәгәя, әмма булганнарында һәм шулай ук вакыйга бара торган урынны күрсәткән өзекләрдә актуаль мәгънә *-р* формасы белән бирелә, персонажларның керүләре-чыгулары турында аңлатмаларда *-р* формасы *-а* күрсәткече белән чиратлаша: Шул wақыт Теллә хуҗа килеп чығар [Татар әдәбияты, 1957, б. 617]; Шул сәгать Байтирәк урырға башлар, қызлар торып өйүләренә қайтып китәрләр [Татар әдәбияты, 1957, б. 621] һ.б.

Беренче драма әсәрләрендә *-р* формасы хәзерге заман мәгънәсе белән генә түгел, бәлки киләчәк заман мәгънәсе белән дә кулланыла: ...Әгәр бу эшләр була қалса, мин ни эшләрмен. ...Йуқ, йуқ, бармам. ...Без, ахры, Аллаға тапшырырбыз. ...Котылырсың бу зинданнан (Бичара кыз). Мисаллардан күренгәнчә, киләчәк заман хикәя фигыль барлыгында – тулы, юклыгында кыска зат кушымчасы ала, шөбһәләнү, гөман итү, ышану кебек модаль төсмерләр белән файдаланыла.

«Рәдде бичара кыз» драмасында сөйләү моментыннан соң башкарылачак эшне белдерә торган *-р* формалы фигыльнең берлек һәм күплектәге I заты тулы һәм кыска кушымча алып кулланыла: ...туйына да, барысына да ақчасын үзем бирем, диде. ...әгәр мәслихәт булса, көндез кереп чығармән, өйләдән соң Закирны алып килермән [Халидов, 1888, б. 6]; ...туйны қай көн икәнен үзем хәбәр бирем [Халидов, 1888, б. 9]; ...Әхтәм абзаңызға үзем әйтерем, туйын да үземездә итәрмез [Халидов, 1888, б. 12]. «Морад Сәлимов» драмасында II зат күплектә *-сыңыз* кушымчасы файдаланыла: Әйуп. Бер хат йазайық: «Өч йөз мең кәҗә тиресе алдым, ике партийа итеп җибәрдем, базарына сатарсыңыз» – диген. Морад. Бай, ике хат йаздым, кызыңызға уқытырсыңыз [Татар әдәбияты, 1957, б. 596]. Әйуп. Иртәгә туй итәлем, насыйп булса, кичәсенә кийәү булып, қыз йанына килерсеңез... [Татар әдәбияты, 1957, б. 609]. «Саран, надан Теллә бай» драмасында да киләчәк заман хикәя фигыль I зат берлектә тулы кушымча белән дә, кыска кушымча белән дә, II зат күплектә *-сыңыз* күрсәткече белән дә кулланыла: Теллә (ачу берлән). Менә бирем мин сезне кийәүгә, сез көчекләрне. Урығыз урақны, мин үлгәч урмассығыз, теләгән кийәүгә барырсығыз, мин исәнлектә сезгә кийәү йуқ [Татар әдәбияты, 1957, б. 619]. Байтирәк (биленә тайанып). Алийа,

бир мең тәнкәне, санап бирем, аптырар дийеп белдеңме [Татар әдәбияты, 1957, б. 620] һ.б.

Шулай итеп, беренче драма әсәрләренең текстларында *-р* формалы хикәя фигыль үзенең традицион, ягъни хәзерге заманны һәм аның төрле мәгънәләрен белдерә алу вазифасын да үти, бу вакытта, I зат барлыкта кыска кушымча белән белдерелә; һәм шул ук вакытта, әлеге фигыль киләчәк заманны белдерү мәгънәсе белән кулланыла, язма китаби традиция буенча I зат берлектә дә, күплектә дә тулы зат кушымчасы ала; җанлы сөйләмә нормасы да файдаланыла, ягъни татар диалектларында актив булган [Юсупов, 1986, с. 71] кыска зат кушымчасы кулланыла.

Шулай итеп, XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган сәнгатьле проза һәм драма әсәрләрендә *-р* формалы хикәя фигыльнең, язма традицияне дәвам итәрәк, хәзерге заманның барлык мәгънәләре белән дә реальләшүе, шул ук вакытта, киләчәк заманны белдереп, аның парадигматик һәм синтагматик мәгънәләре белән дә киңрәк файдаланылуы һәм алга таба өстенлек ала баруы күзәтелә; *-р* формалы хикәя фигыльнең әлеге мәгънәләрне белдерә алу үзенчәлеге махсус рәвештә сайланып алынганга күрә, аларның кулланылышы функциональ-стилистик вариантлылыкны барлыкка китерә дип әйтергә мөмкинлек бирә.

Югарыдагы тикшеренүләрдән күренгәнчә, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, М. Гафури кебек классик әдипләр иҗат итә башлаганда *-а* һәм *-р* кушымчалы фигыльләрнең кулланылышында, традиция дәвам ителгән хәлдә, сөйләмә телгә нигезләнеп тотрыклана торган нормаларга да ныклы җирлек салынганлыгы аңлашыла.

Г. Ибраһимовның хикәяләве эзлекле рәвештә *-ды* формалы категорик үткән заман һәм сирәгрәк *-а иде* формалы тәмамланмаган үткән заман фигыльләре белән бара торган беренче әсәрләрендә, персонаж карашыннан, яисә аның сөйләме буларак тасвирлана торган күренешләр, хәбәрләре *-а* формалы хәзерге заман хикәя фигыль белән бирелә. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) әсәрендә: ...Зәки мәхдүм кергән өйнең манзарасы менә шул рәвештә иде: ...бу кешеләрнең бәғзесе намаз укый, бәғзесе ашый-эчә, бәғзесе йоқлый, бәғзеләре йазу йаза, бәғзеләре пыйалаға эре-эре идеп шәмаил йаза… [Ибраһимов, 1974, б. 401]; ...атасыннан бик җентекләп сораша башлады: – Әти, нигә ул мәдрәсәне себермиләр? Нигә чүпләрне түкмиләр? Нигә бу қадәрле пычрақ тоталар? Нигә айақ астында төрле кийемнәр

wә қара күлмәкләр йата?... [Ибраһимов, 1974, б. 402]. Аңлашылганча, мондый җөмләләр ярдәмендә күренеш хәлләр укучы күз алдында бара кебек тәэсир ясала, әмма әлеге эш-хәлләрнең гадәти булуы да, үткәндә булган эшнең нәтиҗәсе күз алдында булуы да аңлашыла. Бер-ике мәртәбә традиция булып килә торган *-адыр* формасы да файдаланыла: ...Фикер орлығы... мотлақа бик тиз замана тамыр җәйәдер wә бик тиз дөньйаға тараладыр. ...ғақылы бар адәм ...шул фикернең бераз үзгәрүе, зарарсыз булып мәйданға чығуы өчен иҗтиһад итәдер [Ибраһимов, 1974, б. 444] һ.б. Диалогик сөйләмдә, хәзерге заман I һәм II зат-сан белән дә белдерелә:.. Китаптан қарасам беләм, дидем, зиһенемдә бар дип әйтмим. ...Сез берни белмисез, надансыз, қарасам беләмен һ.б. Менә шушы урында бер-ике мәртәбә *-р* формалы фигыль хәзерге заман мәгънәсе белән кулланыла: ...без әйткән нәрсәләрне белерсезме икән? Ник белмәскә, һәммәсен дә белерем. ...белермен, белермен, – дип, мөтәкәббиранә торды [Ибраһимов, 1974, б. 422]. Әмма *-а* формалы фигыль дәвам ителә: ...Мин лөғатне генә белмимен [Ибраһимов, 1974, б. 423]; ...соң дәрәҗәдә шатланамын, ...үзем өчен бөйек Камаль wә шәрәф саныймын [Ибраһимов, 1974, б. 443] һ.б.

Шулай итеп, Г. Ибраһимовның беренче хикәясендә традиция булып килә торган формалар бер-ике мәртәбә генә файдаланыла. *-а* формалы фигыль эзлекле кулланыла. «Яз башы» хикәясе кебек I заттан хикәяләнә торган әсәрләрдә хәзерге заман фигыльләре сан ягыннан күбәя, үткән заман формалары белән берлектә, вакыйганы алып бару көченә әверелә: ...Бүген майның урталары булғанға, қойаш йырақ, ләкин туры һәм матур қарый. ...Бөтен йир йөзе йазның гүзәллеге белән чолғана, һәр йирдә тын ғына, ақрын ғына бер шадлық, wә тәмлик, wә йаңа хәйәт сизелә [Ибраһимов, 1974, б. 54–55] һ.б. Классик әдипләр иҗатында фигыль формаларын куллануны тикшерү эшендә һәрбер әдипнең һәрбер әсәрендә авторның индивидуаль осталыгы ничек итеп чагылуы белән бәйләп карарга кирәклек алгы планга чыга.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» (1907) хикәясендә хикәяләүне *-а иде* формалы тәмамланмаган үткән заман хикәя фигыле алып бара. Хәбәре *-а иде* формалы үткән заман фигыле белән белдерелә торган берничә җөмлә кулланылгач, *-а* формалы хәбәр файдаланыла: ...Татар ханымнарының кечкенә қалфақлары бу wақытта бөтен Йаурупа, Шәрек ханымнары тарафыннан баш киеме уларақ қабул ителгән булғанлықтан, бу җәмғыйәтьтә йефәк көлтәсе шикелле чәчләрдән ясалған төрле прическалар өстендә қалфақлар чәчләргә қа-

далған чәчкәләр шикелле торалар иде... [Әмирхан, 1984, б. 8] һ.б. Яки, киресенчә, башта *-а* формалы хәзерге заман фигыле тезелеп бирелә, аннан соң *-а иде* формалы тәмамланмаган үткән заман хәбәрле җөмлә килә: ...Дустларым, күзләрен мөлайемәнә йасап, йаныма киләләр, бәгъзеләре қулымны қысалар, бәғзеләре дә үбәләр – һәммәсе ғайет белән тәбрик итәләр wә шундый күп ғайетләрне күрүемне телиләр иде... [Әмирхан, 1984, б. 8] һ.б. Хикәяләнү аерым персонаж карашыннан бара торган әсәрләрдә,укучы күреп тора торган кебек итеп бирелгән күренешләр, диалогик кара-каршы сөйләшүләр *-а* формалы хәзерге заман хикәя фигыльнең, гадәттә, кыска кушымчасы белән I һәм II затлары файдаланыла. «Бәйрәмнәр»дә: Репетицийәгә барам, иртәгә әдәбийатка мин дә участвовать итәм [Әмирхан, 1984, б. 23]; ...мин үзеңезне қызғанып әйтәм, мин бөтен бала-чағаларны қызғанам, ...мин сезне надан бичаралар дип қызғанам, ...мин башны йалтыратып алдырып йөрергә бик ойалам [Әмирхан, 1984, б. 24] һ.б.

М. Гафуриның беренче проза әсәрләрендә *-а (дыр)* формалы фигыльләр авторның билгеле бер фикерен турыдан-туры әйтеп бирү чарасы буларак файдаланыла. Мәсәлән, «Ачлык ел» әсәрендә: Бәгъзе wақытта бәхет-дәүләт кире китсә, уйламаған урыннардан бәлақазалар килеп, инсаны зилләтә дучар итәдер. ...Бу кеби ағыр йыллар, дәгел йәтим қалған хатыннарны, бәлки зур байларны қайғыға төшерә, бөтен мәмләкәткә зарар китереп, астын-өскә китерәдер... [Гафури, 1983, б. 19]. «Үги балалар»да: Ғыйлемне дәрд иткән қайда булса да тәхсил итә, теләгән нәрсәсене қайдан булса да табадыр... [Гафури, 1983, б. 36] һ.б.

Димәк, *-а* формалы хәзерге заман хикәя фигыль, үзенең бер үк мәгънәләре белән, төрле әдиптә берникадәр дәрәҗәдә төрлечәрәк вазифа үтәү максатыннан файдаланыла. Мисаллардан күренгәнчә, классик әдипләрнең беренче әсәрләрендә үк хәзерге заманның мәгънәсен *-р* формасы белән белдерү шактый сирәгәя яки бөтенләй дә күзәтелми; традицион язма күрсәткеч татар халкының җанлы сөйләмә варианты *-а* формасы белән алмаштырыла.

Шулай итеп, XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар прозасында *-р* һәм *-а* формалы фигыльләрнең хәзерге һәм киләчәк заманны белдерү вазифасы белән кулланылышында, хәзерге әдәби телдә норма булып ныгыячак нигезгә килүнең эзлекле процесста баруы ачык чагылыш таба; риваятьләрдән килә торган вакыйгаларны бәян итеп, хәзерге заманны белдерү автор сөйләмендә рәттән *-р* формасы белән

белдерелгәндә дә, диалогик сөйләмдә *-а* формалы фигыльгә өстенлек бирелә. Авторның үз исеменнән сөйләп хикәяләнә торган әсәрләрдә *-а* кушымчалы фигыль, үзенең шул вазифасын саклаган хәлдә, автор сөйләмендә активлаша, әсәр I зат күплек саны белән башлана, *-р* формасының хәзерге-киләчәк заман мәгънәсе белән кулланылуы дәвам ителсә дә, *-а* формалы фигыльнең хәзерге заманны белдерү колачы тагын да киңәя, сөйләү вакытында актуаль булган һәм шулай ук даими, гадәти, кабатлаулы эш-хәлләрне белдерә торган мәгънәләре белән файдаланыла, хәзерге заманны белдерә торган башка формалар (*-макда* һ.б.) белән алмаштырылып кулланыла. Классик әдипләрнең сәнгатьле проза әсәрләрендә вакыйга-хәлләрне сөйләп түгел, бәлки тасвирый сурәт ясап хикәяләнә торган беренче әсәрләрендә *-р* формасының хәзерге заман мәгънәсе белән кулланылуы традиция күрсәткече, яисә стилистик чара буларак дәвам ителсә дә, хәзерге заманның барлык мәгънәләре дә *-а* формасы белән күрсәтелә; башка чаралар белән берлектә, һәр әсәрнең үз эчтәлегендә генә чагылыш таба торган образлар системасын барлыкка китерү чарасына әверелә. Фәнни, публицистик, дини-дидактик хезмәтләрдә әлеге фигыль, гадәттә, даими кабатлана торган, ягъни вакытка бәйле булмаган мәгънәсе белән файдаланыла.

*-а* формасының синонимы булган традицион язма күрсәткечле фигыльләр кулланылмый башлагач, хәзерге заманның мәгънәләре фәкать *-а* формасы белән генә белдерелә башлый; *-йур* формасы исә татар прозасында угыз һәм кыпчак юнәлешендә бара торган иҗатны аерымлап карарга мөмкинлек бирә.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар прозасында, хәзерге-киләчәк заманны белдерү өчен, *-р, -а, -а (- дыр), -р (дыр), -йур* формалары кебек, барлык жанр-стильләрдә дә бертигез дәрәҗәдә эзлеклелек белән файдаланылмый, әмма шигъри әсәрләрдә кулланыла торган *-ады -айды, -гани, -ганди* күрсәткечләреннән аермалы буларак, тезмә әсәрләргә караганда азрак санда булса да, чәчмә әсәрләрдә дә урын ала торган *-гай* күрсәткечле киләчәк заман хикәя фигыле күзәтелә.

Татар телен фән буларак өйрәнеп язылган беренче татар грамматикаларында, ягъни Г. Фәезхановның «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» (1887), К. Насыйриның «Әнмүзәҗ» (1895) хезмәтләрендә *-гай* формасы хакында бер нәрсә дә әйтелми, әлеге форма фәкать М. Өметбаев тарафыннан язылган «Татар нәхүсенең мохтәсары» (1901) дәреслегендә очрый [Өметбаев, 1901, б. 28–29].

К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда (1881) *-гай* формасы бер-ике урында гына күренеп китә: И хәкиме заман, ...бу эшне әдә қыйлмақ wә бу мөшкел эшне ачмақ синең қулыңдан килгәненә шөбһәмез йуқ. Барыб аның мөәкелен ачқайсан. Без һәм зийадә миннәтдар булырмыз [Насыйри, 1974, б. 243]. Җиңелчә үгет-нәсыйхәт бирергә җайлаша торган бу форма, фәнни-дидактик хезмәтләрдә эзлекле рәвештә кулланыла. «Кабуснамә тәрҗемәсе»ндә (1882): И уғыл, әгәр шағыйрь булып шиғырь әйтмәк қасд итсәң, җәһәт ит ки, шиғырьдә сүзең рушан булсын, сақлан ки ғамыйз булмағай. [Насыйри, 1975, б. 64]; Имде, и уғыл! Әгәр бер кемсәне мәдех итмәгә барсаң, иске кийем белән барма, йөзең ачық, кийемең пақ, хәтерең хуш булсын, таки барған җиреңдә фәрәх бәхеш булғайсың. ...wә дәхи күп надир хикәйәтләр wә ғарайеб мәсьәләләр, көлдергуче нөктәләр, мөхазарәттан күп сүзләр хифыз қылып, урыны белән ул мәҗлестә хикәйәт қылғайсың... [Насыйри, 1975, б. 65]. «Китабәт-тәрбия»дә (1891): Әй уғыл, һәрбер хикәйәттән бер мәғнә фәһем иткәйсән ки, бәнагяһ, берәү сине бер йирдә йаманлаған булса, аңар қаршы син аны макта [Насыйри, 1975, б. 128] һ.б.

Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, К. Насыйриның фәнни-дидактик хезмәтләрендә *-гай* формалы фигыльнең II зат берлек саны, билгеле бер ритмны саклап, нуль формадагы боерык фигыльләрдән соң киңәш бирү рәвешендәге боеру мәгънәсен ала, бу төрдәге җөмләләрнең күбесе билгеле бер шартларга бәйле булып, шул шартлар үтәлгәндә генә әлеге киңәшләрнең тормышка ашасы аңлатыла. *-гай* формасы шул ук мәгънәсе белән «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә»нең чәчмә өлешендә бер-ике мәртәбә кулланыла: Таһир Зөһрәнең апасына әйтде: Зөһрә солтанға безләрдән сәлям wә доғалар әйткәйсез [Татар әдәбияты, 1957, б. 312]. Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда (1887): Бу ике қошның тәрбийәсендә wә ашамақ-эчмәгендә асла кимчелек қыйлмағайсән, wә дәхи мин сатудан қайтқанча, тәқwәлек йулындан тыш айак басмағайсән, ...булыр-булмас хәсис адәмләр белән әшнәлек қыйлмағайсән... [Фәизхан, 1896, б. 6] һ.б.

*-гай* формасының I зат кушымчасы алган хәлдә кулланылуы Ә. Уразаев-Кормаши кыйссаларыннан башка, тагын Г. Гафуров-Чыгтайның «Тутам» рисаләсендә (1906) күренеп китә: Таки мин «ирләр бойырықчы, хатыннар итағатьле хезмәтче булып қалырға тийеш икән» дәйү инанғаймын [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 359]; Зәүҗем бәйдән сүз алды кем: бән бу утырышта тутамны искә

төшермәйгәймен. ...Бәс имде бән һәм бу утырышта Қазан йағы шәкертләренең әхwәлеңдәй ғыйбрәт алып, заһирдә шәриғатькә хилаф күренгән сүзләргә түзгәймен [Фәтзхан, 1896, б. 364]. Аңлашылганча, I зат берлек сандагы зат кушымчасы белән барлыкта һәм юклыкта кулланыла торган *-гай* формасы бу әсәрдә дәвамлы хәзерге заман мәгънәсенә туры килә торган вазифа башкара.

*-гай* формасы Ф. Кәриминең аерым хикәяләрендә, сатирик эчтәлекле образ барлыкка китерү чарасы буларак файдаланыла. «Җиһангир мәхдүмнең ауыл мәктәбендә укуы» хикәясендә: Бүген мәхдүм анасының Тәғбирнамәсен мәдрәсәгә алып килгән, ...бу рәвешчә уқырға башладылар: «һәркем ирсә төшендә үзен тар җиргә керер күрсә, җәмал ийәсе хатын алғай, һәркем ирсә төшеңдә кыйар, шалқан, чөгендер, кишер wә әшбәһ залиқ нәрсәләр күрсә, қайғы күргәй... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 242].

*-гай* формасының хәзерге татар әдәби телендә дә [Татар грамматикасы, 2002, б. 155], татар теленең урта һәм мишәр диалектларында да *-магай* формасы булып [Юсупов, 2004, с. 482–485] һәм шулай ук гомумтөрки планда язылган хезмәтләрдә, теләккә бәйле төрле төсмерләр белдерә торган кушымча буларак каралуы, төрле телләрдә төрлечә аталып йөртелүе һәм киләчәк заман хикәя фигыле, шартлы теләк, теләк-боеруны һ.б. вазифаларны үтәве мәгълүм [СИГТЯ, 1988, с. 330–333].

XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган сәнгатьле чәчмә әсәрләрнең шигъри тезмәләренә караганда, чәчмә прозада шактый актив булып *-макда, -макда (дыр)* формасы да файдаланыла. Текстларны транскрипцияләгән вакытта *-макда (дыр)* вариантлылыгы хасил була.

Гомумтюркологик планда язылган хезмәтләрдә *-макда* формасының сөйләү моментында башкарыла һәм сизелерлек рәвештә тәмамланып бара торган эш-хәлләрне белдерү өчен кулланылуы ассызыклана [Юлдашев, 1965, б. 153–154]. Өйрәнелә торган әсәрләрдә *-макда (дыр)* формасының, шушы нигезе сакланган хәлдә, башка төсмерләр белән дә катлаулана алуы күзәтелә. К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасында»нда әлеге форма түбәндәге җөмләләрдә чагылыш таба: ...Бераздан бозып, йәнә йазды, мәғрибтән мәшриққа, күк өстеннән, җир астыннан һаман эзләмәктә [Насыйри, 1974, б. 244]; ...Кич қызым барып килмәктә, көндез үзем рисвай булмақта [Насыйри, 1974, б. 267]. Мисаллардан аңлашылганча, *-макда, -макда (дыр)* формасы, сөйләү моментында башкарыла һәм тәмамлануга бару мәгънәсенә

тагын кабатлану төсмере дә кушылган эш-хәлләрне белдерә. Публицистик мәкаләләрендә дә шул ук мәгънәдә кулланыла: ...бу фән төрек телендә wә ғарәп телендә көн бәкөн артмақдадыр [Насыйри, 1974, б. 42] һ.б. Әлеге форма *иде* ярдәмлеге белән кулланылганда да, нигездә, шушы ук мәгънәсе белән реальләшә: Қызның атасы исә, ғайрәт уты җанына кяр қыйлып, хасталыгындан җан биреп җан алмақта. Әмма дөхтәре назнин исә дәхи мәғһүд урынға барып килмәктә. Әмма хәлвәфрүш кичдән таң атқыйнча дәвер сөрмәктә иде [Насыйри, 1974, б. 243].

*-макда* формасы, төрле мәгънә төсмерләре белән кулланыла торган *икән* ярдәмлеге белән килгәндә дә, кабатлана торган эш-хәлләрне белдерә, аның бу мәгънәсе лексик чаралар белән дә ныгытыла: Әлқыйсса, хәлвәфрүш, Әбүғалисина йәрдәме белән, һәр кичә қызны йанына китермәктә wә иртәгә қадәр зәwек-сафа итмәктә икән, моңар қанәғать қыйлмайынча, қыз йанына үзем барыр идем, дип Әбүғалисинаға ғозер wә нийаз итеп, ...илтимас итте [Насыйри, 1974, б. 255].

*-макда* формасы *бул* ярдәмлеге белән кулланылганда, аның сөйләү моментында, тәмамлануга бару мәгънәсе сизелми, киресенчә, тәмамланмаган, кабатлана торган мәгънәсе көчәя: Илче хәзрәте мең бәла wә қайғы-хәсрәт wә үкенеч белән һаман қайтмақта булсын, әмма бу тарафта, ...күрде [Насыйри, 1974, б. 249]; Болар шәһәрне гизеп, эзләмәктә булсын, без килдек илче хикәйәтенә [Насыйри, 1974, б. 251]. *-макда булсын* формасының *утыра торсын*, *куя торсын* кебек тезмәләр, ягъни хәзерге актуаль заман формасы белән алмаштырылуы күренә: ...сарайында утыра торсын, без килдек хәлфәфруш wақыйғасына [Насыйри, 1974, б. 289]. Мисаллардан аңлашылганча, *-макда* формасының К. Насыйри иҗатында сюжет барышының эзлеклелеген алып бару вазифасында кулланылуы күренә.

*-макда* формасы Ә. Уразаев-Кормаши белән Г. Фәезхановның тәрҗемә әсәрләрендә дә шактый сирәк кулланыла.

М. Акъегет белән З. Бигиев иҗатында да шул ук хәл күзәтелә. «Хисаметдин менла»да *-макда иде* формасының берничә җөмләдә кабатланганлыгы хакында алда әйтелде, ә *-макда* күрсәткече тагын да азрак файдаланыла: Қач кичә уйқумда сән мөқатдәсеи күрмәкдәйем, – дип яза үзенең хатында Хисаметдин менла Хәнифә туташка [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 60]. Җөмләдән аңлашылганча, *-макда* формасы, лексик чаралар белән (кач кичә) берлектә, кабатлана торган хәлне белдерә.

З. Бигиев әсәрләрендә *-макда* формасының кулланылышы күзәтелми диярлек, сәяхәтнамәсенең текстында *-макда иде* формасы, бер генә мәртәбә файдаланыла булса кирәк: Вабур хәрәкәтендә дәwам идеп, инәҗәк мәнзилемез улан Қалач нам пристанә йақынлашмақда иде [Бигиев, 1991, б. 294].

Шулай итеп, югарыда карап үтелгән сәнгатьле проза әсәрләрендә *-макда* формасы үз чоры татар әдәби теленең халыклашкан варианты белән язылган әсәрләрдә дә, җәдиди госманлы варианты белән язылган текстларда да бертигез дәрәҗә диярлек кулланыла һәм шуңа күрә функциональ-стилистик аерымлану хасил итә дип әйтеп булмый.

Әмма ләкин Ф. Кәрими әсәрләрендә *-макда (дыр)* һәм *-макда иде* күрсәткечле фигыльләр шактый активлаша һәм төрле жанр-стильдә язылган текстларда төрле ешлыкта кабатлана: үз чоры татар әдәби теленең халыклашкан вариантында язылган сәнгатьле прозасында – азрак, ә инде җәдиди госманлы вариантында язылган сәяхәтнамәләрендә эзлекле булып файдаланыла һәм язма традициянең бер күрсәткече булып санала, димәк, бу әдипнең иҗатында, *-макда (дыр)* формалы хикәя фигыльнең кулланылышында, билгеле бер дәрәҗәдә, эш бүленеше күзәтелә дип әйтә алабыз. Мәсәлән, «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә: Ғосманлы мөхәррирләреннән Әхмәт Мидхәт әфәнде хәзрәтләренең «Ченкәнә» исемендәге бер хикәйәт рисаләсе Истамбул чегәннәре хакында беркадәр мәғлүмат бирмәктәдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 225]. «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» һәм «Бер шәкерт илә бер студент» хикәяләрендә *-макда* күрсәткечле фигыль күзәтелми. «Нуретдин хәлфә»дә: Әлбәттә, ғакыл илә ғыйлем адәмне хуҗа wә сәхиб йасыйдыр, наданлық инсанны қол wә әсир итәдер. Бу қағыйдә хәзер дә wә һәркөн күренмәктәдер [Кәрими, 1996, б. 64]. «Морза кызы Фатыйма»да: Мәғлүмдер ки, хатын-кыз һәр жирдә, үзләренең ғадәтенә күрә, бер төрле зиннәтләнәләр... Вә һәр бересе, үзләренекен гүзәл белеп, башкаларыннан көлмәктәдерләр [Кәрими, 1996, б. 95]. «Хыялмы? Хакыйкатьме?» әсәрендә: Өмид wә хыйалның иң қуәтле, хиссийәтнең иң саф wә мөқатдәсе, асыл, шуйлә адәмнәрдә булынмақтадыр [Кәрими, 1996, б. 122]. Мисаллардан аңлашылганча, *-макда (дыр)* күрсәткечле фигыль сөйләү моментына кадәр башланган эшнең дәвам итүен, сизелерлек рәвештә тәмамлануга баруын һәм билгеле бер дәрәҗәдә кабатлануын аңлата. Кайбер очракта *-макда* формасы *бул* ярдәмлеге белән дә кулланыла һәм аның кабатлануны белдергән төсме-

ре көчәя. Аерым җөмләләрдә *-макда* формасы *бул* ярдәмлеге белән бергә, *-а торган* мәгънәле сыйфат фигыльнең синонимы буларак та файдаланыла: ...кесәсеннән кулъйаулыгын алып, күзеннән чықмақта булған йәшьләрен сөртмәгә башлады [Кәрими, 1996, б. 98]; ...қабарып-қабарып килмәктә булған тулқынлардан башка бер шәй күренмәде [Кәрими, 1996, б. 115]. Кайбер җөмләләрдә *-макда* формасы *исә* ярдәмлеге белән бергә, шарт фигыльнең мәгънәсен барлыкка китерә: Қырымдағы мөселманнарның чүл wә сахра тарафында торғаннары нуғай женесеннән булмыш, үзләренең татар wә мангул сималарын мөхафәзә итмәктә исәләр дә, тәғассебләре wә җәһаләтләре бераз зийадәчәдер [Кәрими, 1996, б. 108–109] һ.б.

Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә *-макда (дыр)* формасы, нигездә, шул ук мәгънәләре белән кулланыла, әмма әлеге текстларда ул ешрак кабатлана. Мәсәлән, «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә: Бу күпернең озынлығы бер верстқа қариб булып, халис тимердән йапылмыш wә астыннан Волга пароходлары гизмәктәдер [Кәрими, 1996, б. 155]; Залның бер тарафында бер миқдар җирне айырмышлар wә бу тирәдә Себергә йуллатмақта булған ристаннарны тулдырмышлар [Кәрими, 1996, б. 156]. Менә шулай, *-макда, -макдадыр, -макдадырлар, -макда иде, -макда бул* формалары эзлекле булып тезелеп бара, *-макда бул* формасы хәл фигыль, инфинитив һәм исем фигыль вазифаларын да үти: «Пушкинский бульвар» намындағы тар wә озын бақчаның бер башы дәхи ошбу Тверская җаләсенә килеп чықмақта булып, бақча эченә, ...Пушкин һәйкәле рәкез ителмеш [Кәрими, 1996, б. 168]; ...wә шимдеге хәлдә Кийев wәлисенең мәэмүр махсусы булып, қардәшләре илә күрешмәк өчен, Петербургка бармақта булдығын сөйләде [Кәрими, 1996, б. 177]. Шулай ук, *-макдадыр* формасы сөйләү моментында дәвам ителә, кабатланып килә торган эш-хәлләрне генә түгел, бәлки гадәти, даими, дәвамлы эш-хәлләрне белдерү өчен дә файдаланыла: Йазын Петербургның эчрүсендәге каналларда пароходлар дәхи эшләмәктәдер [Кәрими, 1996, б. 195]; ...һәр wақыт әсәрләре илә исбат ителә килмәктәдер [Кәрими, 1996, б. 193] һ.б.

Әдипнең «Кырымга сәяхәт» юлъязмасында да *-макда, -макдадыр, -макдалардыр, -макда бул* формалары шул ук мәгънәләре белән эзлекле рәвештә кулланыла, димәк, әлеге формалы фигыльләр, әдипнең сәнгатьле әсәрләре белән чагыштырганда, сан ягыннан да күбрәк һәм шул ук вакытта, мәгънә төсмерләре, ягъни төрле вазифа үтәүләре белән дә активрак кулланыла дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

*-макда* күрсәткечле фигыль Р. Фәхретдин иҗатында да шул ук мәгънәләре белән файдаланыла. «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: Қабан күле илә Булақ Қазан шәһәрене ике бүлемгә аермышдыр. Хәзердә олуғ бүлемдә рус халықлары тереклек итмәктәләрдер. ...Фәқать бер қадәр дәғwәле wә үзләренә хөсне занлы идекләре сүзләнмәктәдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 266]; Хосусән уқымакта улан дәресләремдә бер мәсләк wә күз нуры түгеп тәхсил иткән дәресләремдә, бер мақсат күрелмәс иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268] һ.б.

Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә *-макда* күрсәткечле фигыль, Ф. Кәрими иҗатыннан аермалы буларак, *исә* һәм *имеш* ярдәмлекләре белән ешрак кабатлана: *исә* ярдәмлеге белән шарт фигыль формалаша, *имеш* – хәзерге әдәби телдәге *икән* ярдәмлеге мәгънәсендә, *-макда* күрсәткече белән белдерелә торган мәгънәне көчәйтә, *бул* ярдәмлеге белән килгәндә, төрле мәгънә төсмерләре белән кулланыла ала, әмма бу әсәрдә боларның барысына караганда да ешрак булып, *-макда ид*е формасы кабатлана, *иде* ярдәмлеге, сөйләү моментында дәвам итә торган эш-хәлләрне үткәнгә күчерү белән бергә, автор тарафыннан сөйләнә торган хәлләрне тасвирлау чарасы да булып тора.

Р. Фәхретдиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә дә *-макда (дыр)* күрсәткечле фигыльләр кулланыла: Бу көндәй туқуз йөз йитмеш туқуз йыл мөқәтдәм үтеб китмеш ғарәб сәйахларының йулларыны wә ақрынлық үзәрендә йөрмәкдә улан дәwәләренең эзләрене Самара-Златауст тимер йулы арқылы кисеб китдекендән бу йулилә һәр утырдығымда Ибн Фазлан wә илче һәйәте хатеремә килмәктәдер... [Фәхретдин, 1903, б. 3]. Мисаллардан аңлашылганча, Р. Фәхретдиннең әлеге әсәрендә *-макда (дыр)* формасы, асылда, үткәндәге гадәти, даими эш-хәлләрне белдерү мәгънәсе белән, *бул* ярдәмлеге белән килгән вакытта, сыйфат фигыль, исем фигыль, инфинитив фигыльләрнең мәгънәләрендә кулланыла. Әмма боларга караганда ешрак булып *-макда иде* формалы фигыльләр кабатлана һәм тасвирлау вазифасын да үти.

Әдипнең үгет-нәсыйхәт рухында язылган әсәрләрендә *-макда (дыр)* формасы активрак. Мәсәлән, «Тәрбияле ана»да: Бик йарлы булған өйләр эчендә тәрбийәле ана булса, ул өй олуғ байлардан саналынадыр. Бик бай булған өйләр эчендә тәрбийәле аналар булмаған сәбәбле бик йарлы (фәқыйрь) күрелмәкдәдер. Тәрбияле аналар үз балаларына ғына аш улмай, бәлки мөселманларның барчасына хөрмәт-

ле ана улмақдалардыр [Фәхретдин, 1898, б. 3]. «Асар»да: Ул зат исә һәр wақыт атамыз хәзрәтләренә килүр иде, һәм дә сезә ике шәй өчен килүрем, бере сезләрдә тәғриф китабы вар, шуңа ғашыйқмын, икенчесе чәйне күп һәм қуйы идәрәк эчәрсез, бән исә чәй сәүмәкдәйем, хосуса, қуйы улса, дийүр иде [Фәхретдин, 1909, б. 505]; ...барча йулдашларымыз сәламәт wә хуш wақыт доғаларыңызда йахшы йөрмәктәмез [Фәхретдин, 1909, б. 509] һ.б.

Р. Фәхретдин иҗатыннан соң *-макда* формасын куллану шактый пассивлаша. Г. Гафуров-Чыгтай, Ш. Мөхәммәдев, З. Һади кебек мәгърифәтчеләр һәм шулай ук Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал кебек классик әдипләрнең беренче хикәяләрендә, алда әйтеп үтелгәнчә, *-макда иде* күрсәткечле фигыльләр кулланылу сирәгрәк дәвам итәлсә дә, *-макта* формасы тагын да азрак файдаланыла. Мәсәлән, Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясендә: ...қошларның таwышлары үзгәреп, урыннарының бетүенә, ғомерләренең тәмам булуына хәсрәтләнеп, «әлвидағ-әлвидағ» дийә сайрамақта... [Исхакый, 1998, б. 31]. Шулай итеп, *-макда (дыр)* формасы хәзерге заман хикәя фигыль сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә үзенең вазифасын тулысынча *-а* кушымчалы хикәя фигыльгә тапшыра. Телче-галимнәр «*...-ыр/-ер, -йыр/-йур, -мыш/-меш, -макда/-мәктә* формантлары... әдәби вариантларны томалап, тел чуарлыгы тудыруга гына китергәннәр», – дип нәтиҗә ясыйлар [Мөхәммәдиев, 1982, б. 33], әмма бу фикерне киресенчә аңларга, ягъни әдәби телнең байлыгын күрсәтә алганнар дип тә әйтергә нигез бар.

Беренче драма әсәрләрендә *-макда* формасы кулланылмый диярлек. Мәсәлән, Ф. Халидинең «Морад Сәлимов» драмасында бер мәртәбә укымышлы кеше итеп сурәтләнә торган Морад сөйләмендә бирелә: ...қурқам, Яғқуб бай уғылы Сабир алмасын, бөйлә минем җанымнан қадерле қыз Нуранийәне бернәрсә белмәгән әдәпсез, майға буйалған киемнәр кийеп, йанына барыр хәл йуқ, тир исе килгәнгә бирсәләр, миңа ул wақыт бөйлә wафасыз дөньйада тормақта файда йуқ [Татар әдәбияты, 1957, б. 595].

*-макда (дыр)* формасы шигъри әсәрләрдә дә актив кулланыла дип әйтеп булмый. Мәсәлән, Дәрдемәнднең язма традицион сүз һәм сүзформалар шактый мул кулланылган «Хәят» (1908) шигырендә: ...Санкем, уғыл-қыз туйын итмәкдә ул; қызған уйын / Йөгерешеп, қурчақ төшеп менмәктә ақ бармағына... / ...Ул қалын ил, кем, ғадәмдән сил булып килмәктәдер, / Шәүқләр бирмәктә әлдән бу вөҗүд ирмағына. /

...Ул ғасырлар, кем, һәнүз көтмәктәдер зәүқы хәйәт, / Шәүқләрдер бу әсир төшкән килеп чәчбағына... [Дәрдемәнд, 1980, б. 44].

Г. Тукай иҗатында *-макда* формасы шагыйрьнең өч-дүрт шигырендә, шул әсәрнең эчтәлеге өчен кирәк булган мәгънә төсмере белән катлаулындырылып файдаланыла. Мәсәлән, Г. Тукайның «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» (1907) шигырендә *-мактамы* формасы юл саен кабатлана, әлеге рифмалашып, тезелеп килгән юлларда автор әйтергә теләгән төп мәгънә инкяр ителә: Бер матур қызның нәзек билен қысып қочмақтамы? / Йәки пар йурға җигеп, файтон белән очмақтамы? / Йә сихерле шишәдән абелхәйәт эчмәктәме? / Мәст улып, алямы дөньйадан тәмам кичмәктәме? / Йәки бер ишә wә йә бер қаумә баш улмақтамы?.. [Тукай, 1955, т. 1, б. 104].

Күренгәнчә, Г. Тукайның әлеге шигырендә *-макда* формасы язма традицион элементлар белән бергә, аларның бер төре буларак файдаланыла һәм билгеле бер дәрәҗәдә мәгънәне көчәйтү чарасы буларак аңлашыла.

Шагыйрьнең «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» (1908) поэмасында да әлеге форма, махсус рәвештә сайланып, сатирик образ барлыкка китерү чарасы буларак күтәрелә, ягъни әлеге әсәрнең эчтәлеге өчен генә кирәк булган мәгънә төсмере белән баетыла – сүз-сурәткә әверелдерелә: Иртә берлән қайнамақта бу базар, / Қайда бақсаң, анда тулған сәүдәгәр... / Қайсы сатмақтадыр, қайсы ала, / Берсе алдый шунда берсе алдана... / Иртә берлән қайнамақта ул базар, / Анда да монда қызадыр сәүдәләр [Тукай, 1955, т. 1, б. 209]. Шагыйрьнең «Бәйрәм вә сабыйлык вакыты» (1908) шигырендә *-макда* формасы даими, гадәти эш-хәлне белдерә торган бер тел берәмлеге буларак файдаланыла: Сабый wақтым сағынмақта һәр шағыйрь дә... [Тукай, 1955, т. 1, б. 128]. «Татар яшьләре» (1912) шигырендә дә *-макда* формалы фигыль нәкь шундый ук чара буларак кулланыла: Диққатә лайық хәзерге көн татарның йәшьләре, / Аңламақ, белмәк, тәрәққый, мәғрифәт, хикмәт белән / Әйләнеп һәм нурланып тормақта һәрдам башлары [Тукай, 1955, т. 2, б. 186].

Югарыда искә алынган әсәрләрендәге кебек үк, *-макда* формасы, бу очракта да, башка традицион язма кушымчалар *(-мак)* белән бергә килә: шигырьнең үзенчәлекле аһәңе тасвир ителә.

Г. Тукайның проза белән язылган әсәрләрендә *-макда* формасының кулланылуы күзәтелми. Әмма бер хат текстында файдаланыла: Мәкәрҗәгә барышлый безне зийарәт итәрсез дип, апай берлә ике-

без дә Гурьев тарафына дүрт күз берлә қарамақтабыз... [Тукай, 1956, т. 4, б. 208].

Өйрәнелә торган чорда, *-макда (дыр)* формасына караганда, сан ягыннан шактый аз булып, асылда, III затта, хәбәр булып килгәндә, хәзерге татар әдәби телендәге *-у, -ыш* күрсәткечле исем фигыльләре кебек үк [Татар грамматикасы, 2002, б. 135], *-мак (дыр)* формасының хәзерге заман хикәя фигыль вазифасында кулланылуы күзәтелә. «Әбүгалисина кыйссасы»нда: Хосусан, Әбелхарис кебек адәм аның wәзире булып торғанда, Сөләйман дийүләре булса да, аның қулыннан хәлас мөмкин булмас, һаман моның чарасы сабыр қыйлмақдыр [Насыйри, 1974, б. 221]. «Кырык бакча» да: Моғаммә безнеңчә җомақ wә табышмақ тәғбир қылыныр, морадыңны бер сүз эченә йәшермәкдер [Насыйри, 1975, б. 274] һ.б. «Фәвакиһелҗөләса»да: Бер саран кешедән сорадылар, қатылық wә шиддәттән соң шатлық ни нәрсәдер, дигәч, әйтте: Бер мосафир килеп, тәғам ғарыз қылғанда, мин рузамын, димәкдер, диде [Татар әдәбияты, 1957, б. 216]. Фәнни популяр текстында: Әмма ошбу мослих булучы маддәләр мөғтәдил миқдарда булмаса, ихтимал, зарары булмақ [Насыйри, 1975, б. 90] һ.б.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә *-макдыр* һәм *-адыр* формалары берсе икенчесен алмаштырып та кулланыла: Иштә белдек, йәшь қызның морады қачмақдыр. ...Иштә күрәмез ки, йәшь қыз қараңғы кичәдә йәренге никахлан қачадыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 79].

Г. Тукай шигырьләрендә дә *-мак* формалы фигыльнең хәбәр булып килү очрагы күзәтелә: Суыңнан анда батқақ, монда батқақ, / Синең бар белгәнең җир былчыратмақ...

Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1899) дип исемләнгән беренче хикәясендә *-макда* күрсәткечле хәзерге заман хикәя фигыле *-удә* формасы белән чиратлаша: Ағачларның йафраклары қойылып, үләннәрнең чәчәкләре сарғайып, җәй фасылының бетүенә хәсрәтләр чигүдә, қошларның таwышлары үзгәреп, урыннарының бетүенә, ғомерләренең тәмам булуына хәсрәтләнеп, «әлвидағ-әлвидағ» дийә сайрамақта... [Исхакый, 1998, б. 31]. «Бай угылы»нда: Үземнең кем икәнлегемне белгәнгә, сезнең киленегез булуыма хурлану түгел, һәрwақыт мақтанудамын [Исхакый, 1998, б. 145]. Шулай итеп, әлеге әдип, үзенең беренче хикәяләрендә үк, угыз телләрендә хас булган традицион *-мак* формасын татар халкының җанлы сөйләмә нормасы белән алмаштыра. Дөрес, *-уда иде* күрсәткече

Ф. Кәриминең әсәрләрендә күренә башлый, әмма Г. Исхакый *-уда* кушымчасын эзлекле итеп файдаланмаса да, *-уда иде* формасы, алда әйтелеп үтелгәнчә, әдипнең аерым әсәрләрендә шактый актив кулланыла. Башка әдипләрнең иҗатында күзәтелми булса кирәк.

Хәзерге заман хикәя фигыльнең сирәк кулланыла торган кушымчалары рәтеннән тагын *-учан* формасын күрсәтергә була.

*-учан* кушымчасы *бул* ярдәмлеге белән К. Насыйри әсәрләрендә дә файдаланыла: Әгәр синең сулуың тарайучан булса, ...башың аwыртучан булса, йөрәгең сикерүчән булса, ...башың әйләнүчән булса, қолағың шауласа, ...болардан сихәт табарға теләсәң, дару эзләмәс борын ташлап қарачы тәмәке тартуыңны [Насыйри, 1975, б. 127]. Ф. Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә: Қартларның барысы да болай булмый бит, бәғзыларының табиғатьләре бозылыбрақ, холықлары тарайып китә wә тиз ачуланучан буладыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 220]. «Нуретдин хәлфә»дә: Мужикның күбесе саф иғтиқадлы, туғры йөрәкле wә кичә-көндез үз эшенә тырышып ғомер кичерүчән буладыр [Кәрими, 1998, б. 73]. Г. Тукайның публицистикасында да файдаланыла: Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр уқыған балаларның күңелләре дә назик wәләтыйф булып, анчақ гүзәл wә мөқатдәс нәрсәләрне генә сөйүчән буладыр [Тукай, 1956, т. 4, б. 72]. *-учан* формасы үзенең ярдәмлегеннән башка тагын да сирәгрәк кулланыла. Мәсәлән, Г. Исхакыйның беренче хикәясендә: Туқта әле, қайтып җәмәғатькә сөйләп қарыйм, минем мактау белән генә эш бетми, хатын-қыз эшен алар йахшырақ белүчән... [Исхакый, 1998, б. 46]. М. Гафуриның «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» әсәрендә: Без үземез йалқаучан, төн буйы йегерме рәқағать нәфел намазын уқыймын, йалқаулыққа сәбәп шайтан вәсвәсәсе инде [Гафури, 1983, б. 16].

Шулай итеп, хәзерге вакытта татар теленең урта диалекты һәм мишәр диалектының кайбер сөйләшләрендә хәзерге заман хикәя фигыльнең гадәти мәгънәсе белән кулланыла торган *-учан* формасының [Юсупов, 2004, с. 324–325], әдипләр иҗатында файдаланылуы шактый сирәк күзәтелә.

Шундый сирәк кулланыла торган формаларга тагын киләчәк заман хикәя фигыль вазифасын үти торган *-асы* кушымчалы фигыльләрне күрсәтергә мөмкин. Г. Фәезхановның «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» хезмәтендә дә әлеге форма киләчәк заман хикәя фигыле дип санала, тик автор бу фигыльнең күрсәткечен *-асы* дип кушып карамый, *-масдар* кушымчаларын ташлап, иң элек фәтха кушыла,

аннан соң *-сы килә* дип аңлата [Фәизхан, 1887, б. 23–24]. Әлеге фигыль өйрәнелә торган чорда, билгеле бер дәрәҗәдә сизелерлек булып, Ф. Халидинең драмаларында күренә. Мәсәлән, «Саран, надан Теллә бай хикәяте» драмасында: Қызларға уқытырға шәһәрдән чығасы жалунийа өч йөз сум, ир балалар укытучыға өч йөз алтмыш буласы. Мәктәп салуы, йандырмағы, йақтыртмағы һәм себереп, қарап торырға ике мәктәпкә ике хезмәткәр, бонларға да жалунийа буласы [Татар әдәбияты, 1957, б. 619]. *-асы* кушымчалы киләчәк заман хикәя фигыль тагын авторы билгесез дип санала торган «Комедия Чистайда» (1895) драмасында да күзәтелә: Азрақ сабыр итегез инде, бәлки, йарты сәғатьтән соң күрерсез, аның өчен шул wақытта аңа қунақлар киләсе, инде озақламаслар килерләр [Татар әдәбияты, 1957, б. 637]. Шул ук форма Г. Камалның «Бәхетсез егет» (1898) драмасында да кулланыла: ...Үзеңне-үзең сыйлап-сыйлап йөрмәсәң, аwыруың бик тиз буласы... [Камал, 1978, б. 16]; ...без үзебез дә шул йомшақ аwыз, күптән тотып өйләндерәсе генә бар иде [Камал, 1978, б 23] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, *-асы* формасы киләчәк заман мәгънәсеннән башка вазифалар үтәгән хәлдә дә файдаланыла.

*-асы* формасы киләчәк заман мәгънәсе белән Г. Ибраһимов иҗатында күзәтелә. Мәсәлән, «Яшь йөрәкләр»дә: Чынлап та, ул – быйыл никрут бит, ул қараласы... [Ибраһимов, 1975, б. 117].

*-асы* формасы, өйрәнелә торган чорда язылган текстларда *кил* ярдәмлеге белән бергә, эзлекле рәвештә, теләк фигыльне барлыкка китерә.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган текстларда, сөйләү моментыннан соң башкарыла торган эш-хәлләрне белдерү өчен *-ачак* формасындагы хикәя фигыль дә кулланыла.

Угыз телләренә хас булган әлеге форманың [СИГТЯ, 1988, с. 465] гомумхалык телендә сирәк файдаланылуы, татар әдәби телендә дә шактый соң урнашуы мәгълүм [Тумашева, 1986, б. 58; Абдуллина, 1988, б. 12].

Татар телен өйрәнеп язылган Г. Фәезханов, К. Насыйри, М. Өметбаев хезмәтләрендә *-ачак* формасы күзәтелми, М. Мәхмүтов хезмәтеннән башлап *-ачак* формасы сыйфат фигыль дип өйрәнелә [Мифтахова, 1998, б. 20], Г. Мөхәммәдфәйзи дәреслегеннән башлап (1897) киләчәк заман хикәя фигыльнең икенче формасы булып санала.

Хәзерге-киләчәк заман мәгънәләрендә барлык әдипләр иҗатында бер үк дәрәҗәдә актив булган *-р* формасы белән чагыштырганда,

өйрәнелә торган чорда язылган текстларда *-ачак* кушымчалы фигыльләр, төрле әдипнең иҗатында төрле ешлыкта кабатлана. Мәсәлән, К. Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы»нда да, «Әбүгалисина кыйссасы»нда да шактый сирәк: Бер көн, әлбәттә, сине ойатқа қалдырып, һәлак итәчәкдер [Насыйри, 1974, б. 237]; Минем бу бәхетсез башыма, Аллаһ белсен, ниләр киләчәкдер... [Насыйри, 1974, б. 246]. «Кырык вәзир» текстында *-ачак* формасы ике җөмләдә кулланыла, мәгънәләре бик үк тәңгәл килеп бетми: беренче җөмләдә «әлбәттә» сүзе белән ныгытылып, тәгаенлыкны белдерә, икенче җөмләдә, «Аллаһ белсен» гыйбарәсе фонында, билгесезлекне белдерә, ягъни *-р* формасының синонимы булып кулланыла. «Әбүгалисина кыйссасы»нда *-ачак* формасы түбәндәге җөмләләрдә килә: И мөселманлар, ишетеңез wә агяһ улыңыз, иртәгә мәғарә капусы ачылачақдыр [Насыйри, 1974, б. 210]; И хәким Арсту, ничә ғыйбрәт wә хикмәт тамаша иттерденез. Әмма адәмнең қодрәтеннән киләчәк түгелдер [Насыйри, 1974, б. 271]. Күренгәнчә, әлеге җөмләләрдә *-ачак* формасы киләчәктә булачак эш-хәлләрне, билгеле бер дәрәҗәдә, катгыйлык белән белдерә. К. Насыйриның публицистик һәм фәнни хезмәтләрендә дә әлеге форма, нигездә, шул мәгънәсе белән реальләшә: Биш-алты бала үстерәсез, алдағы көндә балаларыңыз һөнәр wә ғыйлем ийәсе булачақлармы – тәҗрибә қыйлмыйсыз [Насыйри, 1974, б. 48].

Ә. Уразаев-Кормаши дастаннарында *-ачак* формасының хикәя фигыль мәгънәсе белән кулланылуы күзәтелми [Шамарова, 1991, б. 14].

Мәгърифәтчеләр иҗатында *-(й)ачак* кушымчалы киләчәк заман хикәя фигыльнең, катгый киләчәкне белдерерү вазифасында кулланылуын Р.Ф. Мирхәев дөрес ассызыклый [Мирхәев, 2007, б. 79–81]. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында *-ачак (-аҗак)* формасы катгый киләчәк заманны да белдерү мәгънәсе белән файдаланыла: Менла белер ки, Хәнифә туташ бу кичә җаwап куйачақ [Акъегет, 1886, б. 37]. *-ачак* кушымчалы фигыль көтелгән эшнең тәгаен булачагына ышану мәгънәсен белән кулланыла: Бәс, Хәнифә туташ мөнтәзыйр улды (көтте) ки, Ғали бай туйы кеби олуғ шәйлектән Хисаметдин менла хәбәрдәр улып шәһәрә киләчәк wә кәндесене қортарачақ [Акъегет, 1886, б. 78]. *Имеш* модаль сүзе белән бергә кулланылганда, *икән* модаль сүзе кебек үк, катгыйлык тагын дараслану мәгънәсен ала: ...Чөнки бу пойезд йәғни тақым илә мөфти хәзрәтләре Петербургдан Уфайа кәчәчәк имеш [Акъегет, 1886, б. 41]; ...Ах балақай, хәйерле улсын, бу көн туй шәһәргә кидәчәк икән [Акъегет, 1886, б. 51].

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында (1887) *-ачак* формасының катгый киләчәк заман мәгънәсендә кулланылуы тагын да активлаша: Дәһа бер айдан соңра никях мәҗлесе улачаķ [Бигиев, 1991, б. 223]; Муса әфәнде мәхбүс улдисә, Хәдичә туташ wә йөз мең сум көмеш аķча Ғабденнәсыр әфәнденең улачаķ [Бигиев, 1991, б. 226]. һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында да (1890) *-ачак(дыр)* формасының катгый киләчәк заман мәгънәсе белән кулланылышы дәвам ителә: ...йаманлыķ wә бәднамеңез мәйданға чығачаķдыр [Бигиев, 1991, б. 256]; Нижнийдән прогунный атларлә Ķазанға кәләчәкдер, ...атлар тәмам хәзер улғач, йулә чыķачаķдыр [Бигиев, 1991, б. 270].

З. Бигиевнең «Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» (1908) юлъязмасында *-аҗак* варианты ешрак кабатлана: Бөйлә улыр исә, татарның инсанлығы кямил, дини дөньйасы wасиғ, мәғмүр улаҗаķдыр [Бигиев, 1991, б. 297]; Ғаскәрийәтдән ķачмаķ фикере башыма кәлмәмеш, һич кәлмәйәҗәкдер [Бигиев, 1991, б. 300] һ.б.

М. Акъегетнең хикәясендә дә, З. Бигиев әсәрләрендә дә *-ачак* формасы, киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсеннән кала, тагын сыйфат фигыль, исем фигыль, инфинитив мәгънәләрендә дә файдаланыла, әмма, моңа карап, бу әдипләр иҗатында әлеге форма чит булган дип әйтә [Нигматуллов, 1989, с. 100] алмыйбыз, чөнки *-ачак* формасы кебек үк *-мак* һ.б. формалар да күп төрле мәгънәләре белән кулланылышта була.

Р. Фәхретдин әсәрләрендә дә *-ачак* формасы шактый эзлекле файдаланыла. «Сәлимә, яки Гыйффәт» хикәясендә әлеге форманың сыйфат фигыль, исем фигыль, инфинитив мәгънәләре белән берлектә, хикәя фигыльнең катгый киләчәген белдерү очраклары да күзәтелә: Бу хосусны тәфсил итмәкдә күңлемезгә олуғ җәрәхәт пәйда идәчәкдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 271]. «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә: Ләкин бөйлә шәйләрне ғалимләр йазмас исә җәһилләрме йазачаķ. Анлар йазылмадығында милли әдәбийаттымыз нә рәвешчә тәэсис иделәнәчәк? [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 319] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, бу форма, киләчәктә һичшиксез булачак эш-хәлләрне белдерү белән бергә, *имеш* модаль сүзе белән килеп, сөйләүченең (авторның) кире мөнәсәбәтен алып килә.

Р. Фәхретдиннең публицистик хезмәтләрендә *-ачак* формасының киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсендә кулланылуы сирәгрәк күзәтелә.

Ф. Кәриминең сәнгатьле проза әсәрләрендә *-ачак* кушымчалы киләчәк заман хикәя фигыль еш кабатланмый, кайбер мисалларны гына күрсәтә алабыз. «Нуретдин хәлфә»дә: ...җәнабе хақның қодрәте илә йаратылмыш, аның қодрәте wә ирадәсе илә тора, аның әмере wә ирадәсе илә бозылачақдыр. Һәрбер нәрсәне алла бар иткән wә һәр нәрсәне ул йуқ итәчәкдер [Кәрими, 1996, б. 61]. «Морза кызы Фатыйма»да: Ул хәлдә бөтен ғомерләремез қадәр wә хәсрәт илә кичерәчәк, бу йақты дөньйалар безем башымызға тар улачақдыр [Кәрими, 1996, б. 100].

Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләре *-ачак* формасын кулланылышы ягыннан сәнгатьле проза әсәрләреннән аерылмый: әлеге форманың киләчәк заман мәгънәсе белән файдаланылуына караганда, аның сыйфат фигыль, исем фигыль һәм *бул* ярдәмлеге белән башка төрле мәгънәләрдә килә алуы эзлеклерәк бара. Мәсәлән, *-ачак* формасының киләчәк заман индикатив ролендә килә алуына түбәндәге мисалларны гына күрсәтергә мөмкин: ...икенче ишарәт бирелде, димәк ки, йақында айырылачақбыз [Кәрими, 1996, б. 152]; Бу рисаләдә театр wә тамашаханәләр хақында чуқ тәфсыйләткә керешмәйәчәгем [Кәрими, 1996, б. 164] һ.б.

Ш. Мөхәммәдев, З. Һади, Г. Гафуров-Чыгтай кебек мәгърифәтчеләрнең проза әсәрләрендә дә әлеге *-ачак* формасы төрле дәрәҗәдә кулланылыш таба. Киләчәк заман индикатив мәгънәсе белән Г. Гафуров-Чыгтайның «Тутам» хикәясендә ешрак кабатлана: Имде ошбу 2 нче җөзьэ «Тутам» рисаләсендә ихтыйат қылыначақдыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 353]; Әмма бу икенче рисалә тышқы күренешенчә тәүге (әүwәлге) рисаләнең ғакесенә китәчәк wә аңа нәқыйз төшәчәкдер. Йәғни қыз wә хатыннар тарафыннан адвокатлық қыйлып, анларны йапсарачақ wә анлар йағында торып, үткен тел илә ирләргә қаршы торақак wә бөйлә хатын wә қызларның һәр хоқуқта ирләргә тиң wә тигез булуларын эстәйәчәкдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 355] һ.б.

*Икән* ярдәмлеге белән килеп, киләчәктә булачак эш-хәлләрнең ышанычлы икәнлегенә басым ясала: Алай исә минем өмидем бөтенләйгә буш түгел икән wә 17 үктәбер фәрманы буйынча идарәгә халық қатнашачақ, бәс безгә дә хоқуқ булачақ икән, – дидем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 360] һ.б.

Г. Исхакый М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал кебек классикларыбызның сәнгатьле проза әсәрләрендә дә *-ачак* фор-

масы куллану, нигездә, шушы тәртиптә бара, ягъни әдипләр үзләренең әсәрләрендә әлеге форманың төрле мәгънәләрен файдалана, әмма аларның барысында да диярлек әлеге форманың сыйфат фигыль мәгънәсе һәм *иде*, *бул*, *икән* ярдәмлекләре белән бергә килү очраклары сан ягыннан күбрәк күзәтелә, сирәгрәк булып, киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсендә дә кулланыла [Мөхәммәдиев, 1982, б. 36]. Г. Исхакыйда: ...әлбәттә, бер wақыт бөйек хәким улачақ [Исхакый, 1998, б. 38]; ...қабул итсәләр, имтиханға чақыртырлар, чәһаршәнбә көн имтиханнары булачақ [Исхакый, 1998, б. 40] һ.б.

М. Гафури әсәрләрендә *-ачак* формасының киләчәк заман индикатив мәгънәсе ешрак кабатлана. «Ачлык ел яки сатлык кыз» хикәясендә: ...боларның бу айанычлы хәле, әлбәттә, тәэсир итмәйәчәкдер [Гафури, 1983, б. 38]; ...Инде боларны кем тәрбийә итәчәк [Гафури, 1983, б. 29] һ.б. «Үги балалар» хикәясендә: Мәдрәсәдә тәхсил иткән ғыйлемләре дә бик мәғлүм wә ғади булғанға күрә, аларны онытып, зарар итәчәк дәгел иде [Гафури, 1983, б. 35]. Әлеге өзектән аңлашылганча, әсәрдәге иң тәэсирле урынны автор *-ачак* формасының төрле мәгънәләрен кулланып тасвир итә. *-ачак* формасының катгый киләчәкне белдерә торган мәгънәсе җөмләдә лексик чаралар белән дә көчәйтелә: Бәдри инде, әлбәттә, һәрбер эшне баш өсте җиренә җиткерәчәк [Гафури, 1983, б. 79] һ.б.

Өйрәнелә торган чорда иҗат ителгән шигъри әсәрләрдә *-ачак* формасының кулланылуы хакында фикер әйтү өчен нигез бар дип әйтеп булмый.

Г. Тукай «Матбугатыбызның “фәсахәт нәмүнәләре”» дигән сатирик характердагы мәкаләсендә, *-ачак* формалы сүзне һәр ике мәгънәсе белән дә куллана, шулай итеп, мәкаләнең эчтәлегенә туры китерелеп, сүз уйнатыла: ...Киләчәккә өмит зур. Менә тиздән ғали мәғлүматлы кешеләребез өлгерәчәк. ...Киләчәк заман депутатларыбыз да «суқыр трудовик» булып йөрмәсләр. Ай киләчәк! Ул қайчан киләчәк... [Тукай, 1956, 4, б. 196].

*Кыскача нәтиҗәләр.* XIX гасыр ахыры – XX йөз башында иҗат ителгән төрле жанр-стильдәге текстларда хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыль, нигездә, түбәндәге формаларда чагылыш таба: *-а, -а (дыр), -ады, -айды, -р, -йур, -маз, -мас, -макда, -макда (дыр), -гай, -гани, -ганди, -уда, -учан, -асы, -ачак.*

Җентекләп тикшеренүдән аңлашылганча, әлеге заман күрсәткечләре, активлык һәм пассивлык ягыннан, төрле текстта төрле

дәрәҗәдә кулланыла, парадигматик һәм синтагматик мәгънәләренең реальләшүе ягыннан да төрлечә файдаланыла.

*-а, -р, -мас* кушымчалары барлык жанр-стильләрдә дә, эчтәлекне укучыга китереп җиткерүдә, бертигез дәрәҗәдә актуаль була.

*-адыр, -йур, -маз, -рды, -рмыш, -макда (дыр), -гай* кебек традицион язма формаларының, үз чоры әдәби телендә, үзләренә хас булган вазифаларыны үтәгәннәре хәлдә, ничек итеп пассивлашуга, ягъни унификацияләнүгә барулары ачыла.

*-айды, -ады, -ганди, -гани, -уда, -учан, -асы* кебек хәзерге татар әдәби теленең аерым диалектларына хас булган җанлы сөйләмә формаларның да, үз чорында язма әдәби тел берәмлекләре буларак, кулланыла алулары күренә.

*-ачак* формасының катгый киләчәк заманны белдерү мәгънәсенең, ягъни төп вазифасының тәгаенләнеп, төрле авторда төрле дәрәҗәдә хәзерге әдәби телдә дә дәвам ителүе күзәтелә.

Шулай итеп, хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыль, өйрәнелә торган чорда, угыз һәм кыпчак төркеме телләренә хас булган ике әдәби нормада кулланыла, димәк, норманың вариантлылыгы да шушы нигездә бара була. Әлеге әдәби нормаларның норма вариантлылыгы итеп түбәндәге күренешләрне санарга мөмкин:

1) графо-орфографиягә нигезләнеп бер үк кушымчаның төрлечә язылаәйтелә алуы: *-а, -ай, -и, -әй, -маз, -мәс, -ачак, -аҗак* һ.б. Өйрәнелә торган чорда язылган, текстларда *-р* формалы хәзерге-киләчәк заман хикая фигыле I зат берлектә *-м, -мән (-мен),* күплектә *-з, -мыз, -быз,* II зат берлектә *-сән (-сен), -сең,* күплектә *-сез, -сезңез,* III зат берлектә – нуль форма, күплегендә *-лар, -ләр,* ә юклыгында *-маз, -мас; -ма, -май* кушымчалары белән кулланылуы; гарәп графикасында сузык аваз язылмаган сүзләрдә сузыкка бәйле булган вариантлылыкның күрсәтелмәве, текстларны транскрипцияләгәндә генә килеп чыгуы;

2) морфологиягә нигезләнгәне: а) төрләнгәндә бер үк зат кушымчасының тулы һәм кыскартылган, барлык һәм юклыкта төрле формадагы күрсәткечләрен алуы; б) хәзерге-киләчәк заман формаларының үткән заман һәм башка наклонение мәгънәләрендә һәм шулай ук, киресенчә, башка формаларның хәзерге-киләчәк заман мәгънәсендә кулланылуы;

3) синтаксиска нигезләнгәне: фигыль формалары белдерә торган мәгънәләрнең лексик чаралар белән көчәйтелүе.

Әлеге заман парадигмасын барлыкка китерә торган шушы хәзинәдән бер форманың махсус сайланып һәм ешрак кабатланып файдаланылуы бу категориянең функциональ-стилистик вариантлылыгын хасил итүгә сәләтле икәнлеген аңлата.

Шулай итеп, һәр даим үсеш-үзгәрештә яши торган тел системасындагы аерым бер категориягә хас булган берәмлекләрнең билгеле бер чордагы хәрәкәте-яшәеше күзаллана.

*Боерык фигыль.* Хәзерге татар теле белемендә модальлек һәм наклонение дигән категорияләрнең үзләренә хас булган үзенчәлеге махсус аңлатыла. Эш-хәлнең үтәлү-үтәлмәвен реаль факт итеп белдерә торган хикәя фигыльдән аермалы буларак, эшнең реаль булмавы, хикәя фигыльгә каршы куела торган боеру, теләк, шарт һәм кире шарт наклонениеләре белән белдерелә. Наклонение – эш-хәлнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен махсус кушымчалар белән белдерә торган грамматик категория буларак, сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерә һәм модальлек дип аталучы, функциональ-семантик категориянең бер номинанты буларак аңлашыла [Татар грамматикасы, 2002, б. 146]. Гомумтюркологик планда язылган хезмәтләрдә боерык һәм теләк фигыльләре («повелительно -побудительное наклонение»), ягъни боерулы-теләк тудыру дип, берләштерелеп өйрәнелә. Дөрес, I затка караган форма һәм мәгънә повелительно-желательное дип, II һәм III затка караган форма һәм мәгънәләр «повелительно-побудительное наклонение» дип аерымлана. Әлеге мәгънәнең төрле фонетик вариацияләрдәге күрсәткечләре күп булса да, аларны, нигездә, I затта *-кай/-гай,* II затта *-гын/-гыл,* III затта күплектә *-лар/-ләр* кушылган *-сын/-сун* дип, берләштереп карарга мөмкин булуы күрсәтелә [СИГТЯ, 1988, с. 333–340]. «Языки мира. Тюркские языки» хезмәтендә тикшерелә торган борынгы төрки телләрдә, «повелительно-желательное» дип, бергә [Языки мира…, 1997, с. 143, 154], хәзерге азәрбайҗан, татар, төрек телләрендә аерылып карала [Языки мира…, 1997, с. 364, 402].

Татар телен фән буларак өйрәнеп язылган беренче хезмәтләрдә боерык фигыльгә игътибар ителә. Г. Фәезхановның «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» китабында (1887) «фигыль әмере»нә түбәндәгечә аңлатма бирелә: «...Әмер диб бер эшкә бойыруға дәляләт қыйлған сыйғаларны әйтәләр ки, ул сыйғаларның масдар маддәләрендән адәтләрен ташлағач, мөфрәд мохатәб (берлек сандагы II зат) хасыйл булыб, бер хитаб замиры китермәк белән җәмғ мохатб қыйлынур (күплек

сандагы II зат) хасыйл булурлар: йаз, йазыңыз, йазсун, йазсунлар, йазма, йазмаңыз, йазмасун, йазмасунлар» [Фәизхан, 1887, б. 25]. Бу авторда берлек сандагы III затта *-сун ла,* күплектәге III затта *-сунлар лә,* берлек сандагы II затта *-сана,* күплектәге II затта *-саңыз ла,* берлек сандагы I затта *-ыйм ла,* күплектәге I затта *-ыйк ла* кушымчалары алган фигыльләр «үтенү фигыле» дип аңлатыла [Фәизхан, 1887, б. 34].

К. Насыйриның «Әнмүзәж» (1895) хезмәтендә дә II зат боерык фигыле «фигыль әмере» дип атала: йаз, йазыңыз. Монда III зат боерык фигыле хосусый «әмер билям» дигән исем белән бирелә: йазсун, йазсунлар дип, берлек-мөфрәд һәм күплек-җәмғ әмер билям барлыкка килә [Насыйри, 1975, б. 73].

М. Өметбаев «Татар нәхүсенең мохтәсары» дәреслегендә боерык фигыльне «әмер йәғни бойырмаҡ» фигыле дип атый, аның II һәм III затлары булуга гына игътибар итә [Өметбаев, 1901, б. 29].

Боеру фигыле татар теленең беренче дәреслекләрендә үк аерымлануга карамастан, боерык, теләк, ният фигыльләре, 60нчы елларның ахырл–-247]. Л. Җәләй монографиясендә «Фигыль төркемчәләре» дигән тема: «Бу мәсьәләгә элекке куелыштан чыгып килүне җайлырак таптык һәм күзәтүне, гадәттәгечә, боерык фигыльдән башлап китәбез», – дип белдерелә, теләк һәм боерык фигыльләре бергә тикшерелә, I, II, III затларның кушымчалары тарихи яктан яктыртыла [Җәләй, 2000, б. 176–199].

Академик басма буларак дөнья күргән «Татар грамматикасы»нда тикшерү эше модальлек дип башлана: «Боеру модальлеге (боеру наклонениесе (императив-боерык фигыль)», әмма аңлату: «Боеру наклонениесенең категориаль мәгънәсе – сөйләүченең тыңлаучыга эш кушу, эштән тыю, боеру, өндәү, үтенүне белдерү, ...Боеру наклонениесенең күрсәткече – нуль форма», – дип, фәкать наклонение термины гына кулланылып дәвам ителә. Сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерә торган модальлек категориясенең бер күрсәткече булган боерык фигыль әдәби телдә дә, диалектларда да II зат берлек санда – нуль, күплектә *-гыз, -гез* формалары белән, ...III зат формасы сөйләмдә катнашмый торган затны-затларны белдерә һәм берлектә *-сын, -сен,* күплектә *-сыннар, -сеннәр* кушымчалары белән күрсәтелә. Боеру наклонениесенең семантикасы, боеру төсмерләренең төрле чаралар (кисәкчәләр, эндәш сүзләр, интонация) һәм башка формалар (хикәя фигыльнең, шартлы теләк, инфинитивның

күчерелмә мәгънәләре) ярдәмендә, сөйләүче һәм тыңлаучы арасындагы мөнәсәбәтнең нинди булуына карап, боеруның күп төрле төсмерләре һәм күчерелмә мәгънәләре барлыкка килүе билгеләнелә [Татар грамматикасы, 2002, б. 146–154]. «Татар морфологиясе» хезмәтендә, «Модальлек, модальлек белдерү – сөйләмнең төп үзенчәлекләреннән берсе», – дип аңлатма бирелә дә: «Хәзерге татар әдәби телендә формалашып җиткән дип саналган биш наклонение», шул исәптән боеру наклонениесе (боерык фигыль) барлыгын ассызыклый, ягъни «Татар грамматикасы...» хезмәтендәге кебек үк, грамматик категориянең өйрәнелүенә басым ясала [Хисамова, 2006, б. 172–173].

Татар теленең диалект һәм сөйләшләрендә дә боеру наклонениесе, нигездә, шушы ук формалар белән белдерелә, әмма, әдәби телдән аермалы буларак, боеру мәгънәсен бирүдә тагын *-ың, -гын* күрсәткечләре дә файдаланыла, әлеге формалар ярдәмендә сөйләм сөрешенә, интонациягә, императив фигыль мәгънәсенә карап, боеруның гомуми мәгънәсе, таләп итү, үгет-нәсыйхәт, акыл бирү, ялыну, ялвару, өндәү, сорау, искәртү, киңәш итү, кисәтү һ.б. күп төрле төсмерләр белән баетыла [Юсупов, 2004, с. 459–475].

Язма истәлекләрнең морфология тармагы тикшерелә торган хезмәтләрдә боерык фигыльнең өйрәнелә торган чыганакта кулланыла торган формалары күрсәтелә һәм мәгънәләре аңлатыла.

Безнең максат: XIX гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән әсәрләрдә боерык фигыльнең формаларын барлап, аларның нинди мәгънәләре белән кулланылуын анализлау.

XIX гасырның беренче чирегендә язылган Әбелмәних Каргалыйның (1782–1833) «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-бистәви әс-Сәгыйди» әсәре беренче мәртәбә 1845 елда, икенче мәртәбә 1889 елда, М. Гайнетдин тарафыннан иске татар теленнән күчерелеп, 2002 елда басыла. Әлеге әсәрнең аерым сюжетка нигезләнгән һәр хикәятендә мәгълүм берәр вакыйганы автор укучысына сөйләп бара. Хикәят барышында, ачыктан-ачык үзенең мөнәсәбәте белдерелә торган мөнәҗәтләрендә, гыйлем-мәгърифәт, сабырлык-тырышлык турындагы фәлсәфи-публицистик уйлануларында, «Әй газизем», дип башлана торган вәгазьләрендә ул Аллаһыга ялвара, яисә «персонаж»ларының сөйләме рәвешендәге, «диде» дип башлана торган өзекләрендә сөйләүче һәм тыңлаучының үзара нинди мөнәсәбәттә булуларын тасвир итә. Менә шушы урыннарда боерык фигыльнең төрле формалары белән белдерелә торган төрле мәгънәләре файдаланыла.

II зат барлык һәм юклыкта нуль формалы боеру фигыле кулланыла: иңдеребдер айәте, бел [Каргалый, 2002, б. 65], тәәссеф итмә [Каргалый, 2002, б. 79], әйлә бәйан [Каргалый, 2002, б. 82], сөйләмә [Каргалый, 2002, б. 83]. Шул ук контекстта, нуль формасы, *-гыл* күрсәткече белән чиратлаштырыла:... белгел, бел [Каргалый, 2002, б. 62], мәлүл улмағыл, кил, әйләгел [Каргалый, 2002, б. 91] һ.б. Ходага ялварыла торган мөнәҗәттә, нуль форма, *-гыл* һәм *-асән* күрсәткечләре чиратламаштырыла: Берлекеңнең хөрмәтенә, йә Кәрим / Дөньйадан кичер безе сағ-у-сәлим / Һәм вөҗүдең хөрмәтенә, йә Вәдүд / Безләрә тәүфиқ-у-фазлың әйлә җүд / Һәм Рәсүлең сөннәтилә истибнан / Әйләмәкне рузи қыйл бәдил-ү-җан / Ул Хәбибнең хөрмәтенә, йә Иляһ / Кәчүрәсән, бездән улса, һәр гөнаһ / Җөмлә дин қардәшләремезлә бәһийм / Рәхмәт итеп, әйләгел Фазл-у-Кәрам [Каргалый, 2002, б. 66]. Аллаһы Тәгаләдән өмет ителә торган нәрсәләр аның исме – әғзамләрен файдаланып сорала: кичер, әйлә җүд (юмартлык күрсәт), күңел һәм җан рузи қыл (ризыклы ит), барлық гөнаһларыбызны кичер, барлық дин қардәшләребезне йахшы намуслы, рәхимле, хөрмәтле ит. Күренгәнчә, нуль формалы һәм *-гыл, -асан* кушымчалы боерык фигыльләре барысы да Аллаһыга ялвару, инәлү, өмет итү һәм көчле теләкне белдерү өчен кулланыла; *-гыл* кушымчалы боерык фигыль вәгазь чарасы буларак та файдаланыла: Қыйлмағыл шәйхә тәхәллеф, әй мөрид!, ...Санмағыл бикәрә һәм уйыннарын (Шәехкә каршы булма, аның эшләрен уенга санама) [Каргалый, 2002, б. 93] һ.б.

Шуның белән бергә, «катла әмер», ягъни катгый кискенлек белән эш кушылу сурәтләнгән өзекләрдә нуль формалы боеру фигыле рәттән тезелеп бирелә: ...Берен үлтер сән, вирмә әман, ...тиз ор, гәүдәсен уртайа печ, ...қуй аны, залим башыны қыл җөда, ...вирмә мөһләт, кис ләғыйньнең башыны... қуй боны, тиз залимнең буйныны ор... [Каргалый, 2002, б. 87–88]. Мисаллардан күренгәнчә, нуль формалы фигыльләр, эзлекле рәвештә диярлек, *кыйл*, *әйлә* ярдәмлекләре белән тезмә булып бирелә, *әйлә* фигыле *әйләйә* формасында да файдаланыла: қыйас әйлә (чагыштыр) [Каргалый, 2002, б. 69], сәламәт әйләйә иманнарыны ...биһишт әйләйә җайын (урыннарын оҗмахлы ит), доғамы қыйл қабул, йа Рабби, Амин. Көчле теләкне белдерү өчен *-гәй иде* формасы да кулланыла: Үзеңдин ғайрегә, мохтаҗын Илаһ / Дөшермәгәй иде фазлыла һәргяһ [Каргалый, 2002, б. 70]. Үтенечне белдерелгәндә, тезмә фигыль *әйләсәң* формасы белән кулланыла: Нулә, лотфыңдин бези шад әйләсәң, ...йәд әйләсәң [Каргалый, 2002, б. 79] һ.б.

Аерым бер кешегә, яисә күп кешегә мөрәҗәгать итеп, яхшылык теләп боеру мәгънәсе белдерелгәндә *-ың* формасы, тезмә фигыль рәвешендә *идәсез*, *идәсезләр* күрсәткече белән чиратлаштырыла: Диде ул пәйғамбәр-и ғали җәнаб / ...Һәм зәкяте үтәйүб дотың сыйам / Хаҗ идеб зад идәсезләр хасс-у-ғамь [Каргалый, 2002, б. 72] (Зәкятне үтәгәннән соң ураза тотыгыз, хаҗ итеп кайгылы халыкны (ярлылырны) ризыкландырыгыз). Юклыкта да була: ...Кире дүнде қаумөнә мәзкүр нәби / Диде ...ғафил улмаң әсхабе нәғыйм, ...күзеңезлә әйләйүб тәүбә идәсез сәрбәсәр (баштан) [Каргалый, 2002, б. 73]. *-ың* формасы аерым бер кешегә эндәшкәндә нуль формасы белән чиратлаштырыла: «...әүwәл сабыр әйлә ана!», – диләр. Диделәр: «Ана, бераз кенә сабыр итең [Каргалый, 2002, б. 91, 92] һ.б. *-ыңыз (-ыңызлар)* кушымчасы күп кешегә ялыну мәгънәсен аңлата: Диде ахыр: «Әй ғазиз ихванлар / Қуйыңыз, Алла өчен, әй җаннар, ...санмаңыз, ...бәне қурқыр димәңезләр [Каргалый, 2002, б. 97] һ.б.

II зат берлектә *-әсән,* күплектәге *-әсез, -әсезләр* формасы белән таләп итү мәгънәсе белдерелә. ...Диде: мәшғуль итәсән, ...сүндерәсән һәм сираҗе аль илә [Каргалый, 2002, б. 64]; ...Сыйдық илә бу кяр таләб / Киләсән бу қапуйа, улдықда шаб (Дөреслектә шундый таләп: яшь егет булып бу капуга киләсең) [Каргалый, 2002, б. 84] һ.б.

Сөйләүченең тыңлаучы аша III затка бирелә торган катгый әмере *-сын* кушымчасы белән күрсәтелә: Диде шәйех: ...вар, әлендин әргамен ал, тормасын / Бәлхә варсын, безләрә күренмәсен / Йитде, билендин алубән әрғамый / Алды балтасын, дир: Әй адәми! / Шәйхемез-солтанымыз әмер әйләде / Бәлхә варсын, дормасын бонда, диде [Каргалый, 2002, б. 95] һ.б. III затка каратылган *-әләр* формасы киләчәктә өмет итү мәгънәсе белән кулланыла: Ғазали хәзрәте «Мишкәте әнвар» / Китабыдин моны төркийә бичар / Идебдер тәрҗемә ба нәзым әбьйат / Өмиде: бусәбәбле идәләр йәд / Догаи хәйре идәләр бу фәсыйхә (Килештереп, матур итеп язылган тезмә бәетне язучыны искә алсыннар, хәерле догада булсыннар) [Каргалый, 2002, б. 69].

Шулай итеп, Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә төрле мәгънәләре белән нуль формалы, *-гыл,* берлек һәм күплеккә каратылган, *-ың, -ыңыз,* берлек санда *-әсән (-асың),* күплектә *-әсез, -әсезләр,* III затта *-әләр* күрсәткечле фигыльләрь, гадәттә, *кыйл*, *әйлә*, *ит* ярдәмлекләре ияртеп, төрле төсмерләргә баетылган боеру мәгънәсе белән кулланыла; боеруда көчле теләк белдерелгәндә *-гай* формалы теләк фигыль файдаланыла. Әлеге формаларга аерым

стилистик вазифа йөкләнә дип кистереп әйтеп булмый, чөнки беренче хикәяттә Багдад хәлифәләренең Басра шәһәрендә яшәгән рухани Хәсән Басрый (642–728) белән шул ук шәһәрдә яшәгән атаклы мистик шагыйрә Рабига Гадәвиянең (753 елда үлгән) үзара фикер алышуында да, башка очраклардагы кебек үк, нуль форма, *-гыл, -әсән* һ.б. күрсәткечле фигыльләр кулланыла, әмма алар сүз җаена туры китерелеп, төрле ешлыкта кабатланырга мөмкин.

Шул ук хәл авторның лирик шигырьләрендә дә күренә. «Изанамә-и хаҗи мәрхүм, Мөхәммәд бай мәрхүмгә» дип, тыңлаучыга эндәшеп язылган шигырендә, боеру-теләк мәгънәсен бирүдә дә төрле формалар кулланыла: Хақ Тәғалә қыйлсын ғалә, пасбан улсын йазит, малыңа улма ғорур, кәндеңә йулдаш иденмә, йулдаш әйлә, бел, дыңлағайсән сән боны, бул хәләс, дотмағыл, ғоррә улма, и җәwан, бел ки, бел ки, ғыйбрәт әйлә, бақ, ғоррә улма, қолаққа йахшы сал [Каргалый, 1884, б. 109]. Кабатлану ешлыгы ягыннан, башкаларга караганда, барлык һәм юклыктагы нуль формасының күбрәк кулланылуы күренә. Шуның белән бергә, төрле әсәрләрдәге Аллаһы Тәгаләгә ялвару, өмет итү рәвешендә бирелә торган юлларда *-сын, -гайсән* формалы боерык фигыль белән белдерелү игътибарны җәлеп итә. Һәр яктан бограхан-аристократ төрки юнәлешендә бара торган әсәрдә боеру мәгънәсенең сөйләмә рәвештә белдерелүе аның телен татар укучысы аңларлык хәлгә китерә.

Ә. Каргалыйның чордашы Һибәтулла Салиховның (1794–1867) 1856, 1858, 1900, 1903 елларда басылган «Төхфәтел-әүлад», «Китабы мәҗмәгаль адәб» һәм башка әсәрләре, асылда, шушы ук юнәлештә язылa. Автор әдәпле, итагатьле, иманлы, мәгърифәтле булырга өнди, шул ук вакытта дөньяның мәрхәмәтсезлеге дә фаш ителә. Бу авторда да күп төсмерләр белән баетылган боеру-теләү мәгънәсе төрле формалар белән белдерелә, әмма аның берсе ешрак кабатлана. Әсәр беренче юлларында ук Аллаһыга эндәшеп башлана: Иғанәт эстәрем исемеңлә Алла / Сәнәм улдыр сәңә әлхәмделилла / Сәнең исемең телемдә вирдәм улсун / Дәхи хәббең күңлемдә дәрдем улсун [Салихов, 1856, б. 2]. Аңлашылганча, *Йәрдәм телим исемең илә Алла, Мактаwым шулдыр сиңа әлхәмделилла, Синең исемең телемдә доғам булсын, Дәхи йаратуың күңлемдә теләгем булсын*, дигән юлларда, Аллаһыга ялвару, догам булсын, теләгем булсын кебек, ярдәмлеге *-сун* кушымчасы алган кушма фигыльләр белән белдерелә [Салихов, 1856, б. 2]. Әлеге фикерне нуль формадагы *кыйл* һәм *ит* ярдәмлеге белән ясалган кушма

фигыльләр һәм *-гыл* күрсәткечле фигыль дәвам итә: сабит қадим қыйл, қабул ит, йә Аллаһы, итмә мәхрүм ата-анамлар илә мәрхүм. ...виреб ғали сәғадәт әйләгел шад, насыйб ит җәннәт раузат ризван [Салихов, 1856, б. 3] һ.б.

Ш. Зәки шигырьләрендә боерык фигыльнең форма һәм мәгънәләренең кулланылышы А. Йосыпов тарафыннан җентекләп өйрәнелә [Юсупов, 2006, с. 96–100].

Г. Кандалый иҗатында боерык фигыльләрнең файдаланылуында традиция дәвам ителгән хәлдә, бу максат өчен яңа кушымчаларны файдалану да күренә. Аллаһыга ялыну, үтенүне теләү өчен, алда тикшерелгән авторлардагы кебек үк, нуль күрсәткечле боерык фигыль файдаланыла: ...Иляһи, мин сабырсызны / Сабырлық йулына күндер [Кандалый, 1988, б. 73]; ...Иляһи бир сабырлыкны [Кандалый, 1988, б. 79] һ.б. Шул ук максаттан *-гыл* һәм *-асән* күрсәткечле фигыль кулланыла: Иляһи, син айырмағыл / Бу чәйдин без зәғыйф қолный / Эчәрсә чәй бетәр булса / Алырға вирәсән полный [Кандалый, 1988, б. 86] һ.б.

Шул ук формалы боерык фигыльләр белән, Аллаһыга гына түгел, чибәр кызга, табигать күренешләренә, укучыларга да мөрәҗәгать ителә: ...Қолақ салғыл моңа, җаный [Кандалый, 1988, б. 86]; Көмеш қашық илән алың, ...балыңны измәгел [Кандалый, 1988, б. 87]; Әйә йил, исмәгел бик тиз / Бәнем хәлем итеп йиткез [Кандалый, 1988, б. 88] һ.б.

Г. Кандалый үзенең шигырьләрендә чибәр кызларга нәрсә эшләмәскә кирәклеге хакында үгет-нәсыйхәт бирә, бу очракта нуль формалы боерык фигыльнең юклык формасы активлаша: Буш сүзләргә қолақ салма / Бәнем күз йәшемә қалма / Гомергә хур булып қалма... [Кандалый, 1988, б. 107]; ...Әйа җаным, қызыл алма / Ки бәндин ғайригә варма... [Кандалый, 1988, б. 108] һ.б.

II зат берлек сан *-ың,* күплек сандагы *-ңез* кушымчасы күпчелеккә юнәлтелеп, гафу, үтенүне белдерә: Ғайеп итмәңез сез безгә / Ғыйлемлек булмады бездә [Кандалый, 1988, б. 74]; ...Үзең сақлансаң, сәне Ходa сақлар / Бу сүзләрне йахшы аңлап торың имди [Кандалый, 1988, б. 113]. *-асың* кушымчалы фигыль аерым кешегә юнәлтелеп, теләкле киңәш бирү мәгънәсен аңлата: Бу хатымны қабул итеп аласың, / Қабул итсәң, читен өзеп қаласың [Кандалый, 1988, б. 171] һ.б.

III зат берлектә *-сен (-сүн)* кушымчалы фигыль белән Аллаһыга ялварылып, билгеле бер эш-хәлнең үтәлүе өмет ителә: Ходай бирсен бәңа түзем / Ирештерсен үзе Алла,... / Күрештерсен үзе Алла [Кандалый, 1988, б. 90]; ...Хақ Тәғалә ғашыйқ қыйлды бәне сәңа, / Фазле

берлән үзе бирсен сәне бәңа... / Теләкләрне қабул қыйлсын бер Ходаем... [Кандалый, 1988, б. 109] һ.б.

Шул ук кушымчалы фигыль белән кешеләргә матур теләк теләнә: Қунақ булдық түреңездә / Зикер әйтик үзеңезгә, / Иман нуры йөзеңезгә, / Нур балқысын йөзеңездә [Кандалый, 1988, б. 95] һ.б. Яман теләк тә теләнә: ...Башың төшсен сәнең йаманатларға [Кандалый, 1988, б. 114]; ...Йә алдалап, үзеңне бер мут алсын / Утырыр йиреңне, барғач, ут алсын [Кандалый, 1988, б. 166] һ.б. Китерелгән өзекләрдән аңлашылганча, Г. Кандалый шигырьләрендә, II һәм III зат берлек һәм күплектәге боерык фигыльләрь эзлекле рәвештә, нуль формада, *-гыл, -асән, -асың, -ың, -ңез, -сен (-сүн)* күрсәткечләре, боларга караганда сирәгрәк булып, *-асың, -санә* кушымчалары белән, катгый боерудан йомшак теләк-киңәш бирү, үтенү мәгънәләре белән файдаланыла.

Боерык фигыль формаларындагы мондый функциональ бүленеш, берникадәр тайпылышлар белән, без өйрәнә торган чорда язылган башка текстларда дәвам ителә. Боерык фигыльнең нуль формасы белән *-гыл, -ың* кушымчасының чиратлашып кулланылуы Г. Чокрый иҗатында чагыла. «Мәгәр безгә» шигырендә: Җитәр безгә җиһанда бу ғазаби, / Илаһи, бирмәгел аңда ғазаби... [Татар поэзиясе..., 1992, б. 333]. «Мәгърифәт йулы» шигырендә: Әгәр қалмай дисәң барған йулындин, / Салиқлар кәруанын күзлә уңындин... / Тәмәллек қыл алырға һәм чырағын, / Тәүазыйғлә қыла күргел, сорағын... [Татар поэзиясе..., 1992, б. 336].

Күренгәнчә, бер үк шигырьдә боерык фигыльнең нуль формасы да, *-гыл, -гын, -ың* күрсәткечлеләре дә файдаланыла. Шагыйрьнең башка әсәрләрендә дә шул ук хәл күзәтелә: Әй ғәзиз қәрдәш, әгәр булсаң кәрим, / Қыл тәмийз: буш қуйма имгәкләрем, / Фәһем идеб, инсаф илә уқың аны, / Тәхсин итең, гәрчә күбдер ноқсаны... [Татар поэзиясе..., 1992, б. 337].

М. Йомачиковның «Бәйет» шигырендә, нәзек билгә ялынуялвару эзлекле булып боерык фигыльнең *-гыл* формасы белән сурәтләнә: Кичә-көндез күзем сездә / Қабул қылғыл кәламемне ?.../ Қашың кийереб, күзең сөзеб, / Қабул қылғыл кәламемне. [Татар поэзиясе..., 1992, б. 335]. Дини-дидактик һәм дөньяви-этик әсәрләрдә *-гыл* формалы боерык фигыль өстенлек ала дип әйтергә мөмкин, мәсәлән, «Китаби мөстәтаб фәүз-әл-нәҗат» (1895) әсәрендә: ...Сигездер белгел әхкәм шәриғать, / Белүрсән булсаң әзәһел тәриқать... / Телеңне сақлағыл дәүләт күрүрсән, / Тел озын бәндә булсаң, ләғнәт йийәрсән,

/ Телеңне сақла – михнәтдин қотылғуың, / Wә һәрни күб бәлаләргә тотулғуың… һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Бүз йегет» (1874) әсәрендә нуль форма, *-ың, -ыңыз, -гыл* күрсәткечле боерык фигыльләр берсе икенчесе белән алмаштырылып файдаланыла: Җан, җан йарым кәлгәни, төшдә күрдең сән бәни, / Қушылыр көн булған йуқ, сабыр иткел сән әле [Уразаев-Кормаши, 1878, б. 2]; ...Нә йирлек сән, йирең әйт, эзләп барсам, илең әйт [Уразаев-Кормаши, 1878, б. 5] һ.б.

Аңлашылганча, нуль формалы боерык фигыль гадәти эш кушуны, *-гыл* формасы билгеле бер дәрәҗәдәге катгыйлыкны белдерә, гадәттә, алар берсе икенчесе белән чиратлаштырылып кулланыла. *-ың, -ыңыз* күрсәткечле боеру, берникадәр үтенү-хөрмәтләү төсмерләре белән бер яки берничә кешегә берьюлы эндәшкәндә файдаланыла.

«Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1879) әсәренең тезмә өлешендә, Аллаһыга ялыну, алда тикшерелгән авторлардан аермалы буларак, «...шарт фигыль белән уртак булган *-са* формасына II затның кыскартылган аффиксын алып барлыкка килгән [СИГТЯ, 1988, с. 340] *-саң* кушымчасы белән белдерелә: ...Зөһрә әүwәл кичә-көндез уйқу алмай, аш эчмәй Хақ Тәғаләгә зарилық қыйлып айғаны: Пәрвәрдикяр рәхимә, кодрәтең киң, Ходайа, / Мин бичара қолыңа рәхим қыйлсаң, Ходайа, / Таһирҗанның хәсрәтен бар қыйлыб сән, Ходайа, / Ачық йөзен күрмәгә зар қыйлыб сән, Ходайа, /Мәхәббәтем йарасын бирсәң икән, Ходайа, / Ғыйшық утын Таһир һәм күрсә икән, Ходайа [Татар әдәбияты, 1957, б. 291].

Мөнәҗәтнең эчтәлегеннән аңлашылганча, *-саң* кушымчалы фигыль елап-сыктап ялынуны, ярдәм теләп үтенүне белдерә, кабатланып килеп, көй- моңга төрелә, гозер Алла Тәгаләгә үтемлерәк итеп җиткерелергә тырышыла.

Кыйссаның чәчмә өлешендә, *-са* кушымчасына II зат күплек саны *-ңыз* күрсәткече һәм *-чы* кисәкчәсе кушылып, шулай ук ялынулыбоерулы теләк-үтенү хасил була: И апа, бу көн кичкә Таһирны бер аулақ йиргә сақлап йөрсәңезче [Татар әдәбияты, 1957, б. 319]. И апа, бу көн кичкә Таһирне бер аулақ йиргә сақлап қуйсаңызчы [Татар әдәбияты, 1957, б. 328]. Аннан соң тезмә юллардагы *-саң* кушымчалы ялыну китә: Падишаһым, әльәман, хан солтаным, әльәмән, / Рәхим қыйлсаң қузыйңа, олуғ ханым, әльәман... / Әүwәл безне йаратқан бер алладан теләймән, / Сәбәб булған үлемгә икенче сездән теләймән, / Ғарип мескен қаныны бағышласаң, әльәман, / Йәтим қузый қаныны бағышласаң, әльәман... [Татар әдәбияты, 1957, б. 334] һ.б.

Кыйссаның чәчмә өлешендә тагын хәзерге заман хикәя фигыльнең II зат берлек сан кушымчасы *-әсән (-әсәң)* белән әйтелә торган фигыльләр контекстка туры китерелеп, билгеле бер дәрәҗәдәге катгыйлык белән теләк-боеруны аңлата: ...болар үсеп бәлиғ булғаннарында, Аллаһе Тәғаләнең фәрманы берлә, қызыңны Таһирға бирәсәң, – диде... [Татар әдәбияты, 1957, б. 289]; болар бақчаға киткән wақытларынды, миңа килеп хәбәр бирәсәң, үз күзем белән күрим, – диде [Татар әдәбияты, 1957, б. 298] һ.б.

М. Акмулланың «Даменла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» шигырендә (1892), Мәрҗанигә һәм укучыларына эндәшкән урыннарда барлыкта *-ңыз,* юклыкта *-маңыз* формалы боерык фигыльләр кулланыла: Уйламаңыз «Җарудә»не күргән юк дип... [Акмулла, 2001, б. 13]; ...Даменла икәнеңез исемездә / Фәқыйрьне дә алыңыз исеңезгә [Акмулла, 2001, б. 14].

Автор үз-үзенә эндәшкәндә дә нуль формалы боеруны куллана: Ақмулла, күп сөйләнмә, инде җитәр! / Үзеңнең қайғыңны күр, ғомер үтәр... Сәфәр алыс, инсаф қыл, Хакдан ойал, / Борынғы қабәхәтлек йитәр, энем [Акмулла, 2001, б. 31]; Кечрәйтсәңез, кечрәйергә мин йарайман / Үзеңез зурайырға йарасаңыз [Акмулла, 2001, б. 32] һ.б.

Муллаларга мөрәҗәгать итеп язган шигырьләрендә нуль формалы фигыль кулланыла: Бөрадәр, син үзеңне ихтисап ит, / Мәрҗанине мөҗтәһиттән син хисап ит, / Йир йөзенә нуры төшкән ул бер қойаш, / Ул қойашның нурыннан иқтибас ит! [Акмулла, 2001, б. 35]; ...Әфәндем, Мәрҗани кем, үзеңез кем / Тәнаwел қыл қатерәи данийасен [Акмулла, 2001, б. 40] һ.б.

III зат берлек сандагы барлык *-сын* һәм юклыкта *-масын* формалы боерык фигыль Аллаһыга ялвару мәгънәсендә кулланыла: Ходайым инсаф бирсен күңлеңезгә... [Акмулла, 2001, б. 36] һ.б. Тормыш-көнкүреш тәҗрибәсен гомумиләштерү белән боерулы-теләк мәгънәсен аңлата: Иң әүwәл пақләү кирәк эчнең керен / Эчтә тулып йатмасын нәҗес-эрен, / Аһ дәриға, эч тазарсын, эч тазарсын / Булмаса – файда булмас қоры белем... [Акмулла, 2001, б. 36] һ.б. М. Акмулланың бу әсәре аерым шәхесләргә турыдан-туры эндәшеп, мөрәҗәгать итеп язылганга күрә, боеру наклонениесенең төрле формалары кулланыла.

Г. Тукайның аристократ-абруйлы шигырьләрендә боерык фигыль ерак гасырлардан килә торган традицион формасы белән кулланыла. «Әлгасрел-җәдит» журналы чыга башлауга куанычын белдереп, ягъни гыйлемле, белемле, тырыш булыйк, дөньяда болгарларның булуы-

на ышандырыйк дип, газета-журналларның тагын чыгуына өмет итеп, «Чөнанча бездә...» башламыбелән язылган шигырьдә II зат күплектәге боерык фигыль *-ың* кушымчасы белән бирелә: ...Берең уқып, берең улың сәмиға (Берегез укып, берегез ишетегез), ...Ки сез, қартлар, егетләр, дөхтәриләр / Улың бу журнала һәп мөштәриләр (Барыгыз да бу журналга язылыгыз). *-ың* күрсәткече *-ыңыз* формасы белән чиратлаша: ...Эстәңез: сезнең хәрир мәндилеңез / Иштә бу журнал ирер кәндилеңез (Теләгез: сезнең ефәк яулыгыгыз / Бу журнал сезнең шәмегез) [Тукай, 1985, б. 29] һ.б.

Сөйләмә тел берәмлекләре әдәбиләштерелеп язылган шигырьләрдә II зат күплек саны *-гыз* кушымчасы белән бирелә: ...Шәкерт, студент – бары / Дарга асылғаннары / Сез бу арысланнарый / Онытмағыз тидийә [Тукай, 1985, б. 40]; ...И «Уқлар» мөхбирләре! Қызғанмағыз уқларны / Исраф итмәгез уқларны, атмағыз сез йуқ-барны [Тукай, 1985, б. 73] һ.б.

Абруйлы иске татар телендә язылган кайбер шигырьләрдә *-гыл* кушымчалы II зат берлек сандагы боерык фигыль кулланыла, әмма нуль формасы белән чиратлаштырыла: ...Сән улғыл хәзрәти Хәттаб, бетер һәп потлари табтаб, ...Ки сән лотфыңла тәфриқ ит-айыр әғляйи әднадан [Тукай, 1985, б. 139] һ.б.

«Мужик йокысы» шигырендә II зат берлек саны нуль формалы боерык фигыль белән кулланыла: Ник йоқлыйсың, мужик? / Йаз җитте, һәм үсте / Чирәмнәр йортыңда / Тор, уйан, күтәрел!... / Үз-үзеңә қара [Тукай, 1985, б. 31]; ...Хақының, балаң ач / Ашарға булмағач / Бу көнне күргәнче / өйеңне ташлап қач [Тукай, 1985, б. 32]. Алга таба, авторның барлык, шул исәптән абруйлы иске татар телендә язылган шигырьләрендә дә, нуль формалы боеру фигыле эзлекле кулланыла: ...И қаләм! Китсен әләм, сән әйлә безне шадыман, ...Без өсәраи, көсаляи дә сәүқ ит һиммәтә / Қыйл тәрәххем милләтә – қалдырма, зинһар, зилләтә, ...Қараны йаз қара диб һәм иғтираф ит (әйт) ақны ақ... [Тукай, 1985, б. 56]. Анлашылганча, Г. Тукайның лирик геройга эндәшеп языла торган шигырьләрендә, боерык фигыльнең нуль формасы еш кабатланып, укучыга җиткерелергә тиешле төп фикерне тасвир итеп бирү өчен уңай бер чара буларак күтәрелә. Бу төр фигыльләр, нигездә, тиңдәш кисәкләрнең тезмәсе буларак кулланыла, яисә аерым бер сүз берничә мәртәбә кабатланып бирелә. Нуль формалы боерык фигыль *-чы, -санә* кисәкчәләре белән бергә үтенү мәгънәсе белдерелә: Чықчы, и фикрем қойашы! Китсен өстеңнән болыт / Бу

үлек вөжданны җанландыр, җылың берлән җылыт, ...Бер йөзең күрсәтсанә туғсын гүзәл көннәр минем / Чәчкәләр атсын өмид бақчамда ал гөлләр минем, ...Мин караңғыда хәзер, үтсен бу таң атмас кичәм [Тукай, 1985, б. 29] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, нуль формалы һәм кисәкчәләре белән кулланыла торган II зат боерык фигыле *-сын* кушымчалы III зат берлек саны белән чиратлаша, катгый боеру мәгънәсе белдерелә. Бу фигыльнең алдагы мисалларда да шундый ук мәгънә белән кулланылуы күренә: ...Будыр шатлық вирән дәрдле қолубә / Қолубе шат улмайан – варсын клубә (Будыр шатлык биргән кайгылы күңелгә / Күңеле шат булмаган – барсын клубка) [Тукай, 1985, б. 37].

Г. Тукай иҗатында боерык фигыльләрнең сурәт ясау үзенчәлеген аерып алып өйрәнү зарурлыгы күренә.

Татар прозасын хикәяләүнең беренче төренә караган К. Насыйри кыйссаларында да боерык фигыль формаларының бу рәвешле вазифа башкару үзенчәлекләре саклана, кайбер яңалыклар да күренә. К. Насыйриның «Кырык вәзир» кыйссасында (1868) нуль формалы боерык фигыль сөйләүче тарафыннан тыңлаучысы бер генә зат булган очракта әйтелә, традиция буларак, барлыкта һәм юклыкта эш кушуны, боеруны аңлата. ...Анасы йанына алып бар. ...Үз башыңны қотқарырға чарасын күр, ...син аны элгәре үтер. ...Миңа бераз адәм хазерләп бир. Бу сүзне икенче мәртәбә әйтмә,... йахшы атны буғазла. Монда утыр [Насыйри, 1975, б. 221–249]. «Кырык бакча» (1880) текстында да, нигездә, шушы ук хәл дәвам итеlә: – Мә, эч, диб, кийәwенә бирде. ...тимә, тимә, ул тәсбих әйтә. И Фәйрүз, бу хатны фәлән кешегә илтеп бир, миңа алдан җаwап китер... [Насыйри, 1975, б. 269–280].

К. Насыйриның әлеге әсәрләреңдә, эш башкарырга тиешле кешеләр берничә икәнлеге мәгълүм булганда, боерык фигыльнең *-ың* кушымчасына тагын күплекне белдерә торган *-з* формасы да кушыла. «Кырык вәзир»дә: Өйне аулақ қалдырып, сез мондан китеңез, ...сез дәхи хафа қылмаңыз. Уғылларын йанына чақырып әйтде: ...Мин үлгәч, йахшы, пақ итеп йуыңыз, wә йахшылап тәрбийә қылып күмеңез. И вәзирләр, мине падишаһ итеңез. Тиз тотып китереңез... [Насыйри, 1975, б. 250–269].

«Әбүгалисина кыйссасы»нда (1881) әлеге формалар берсе икенчесен алыштырып, чиратлаштырып кулланыла башлый: Менә ул җадулар. Җибәрмәңез! Тотыңыз. Аллаға шөкер, қулға керде – дип, һәр тарафдан һөҗүм қыйлдылар. Барча халықлар җыйылып, җибәрмә, җибәрмә, тотып бәйлә, – дип, бер олуғ ғауға купты... [Насыйри, 1974, б. 213] һ.б.

Падишаһка мөрәҗәгать итү, һәрвакытта да диярлек, *-ыңыз* кушымчалы фигыль белән башкарыла: бу фигыльләр бер үк контекстта *-ың* булып та, *-ыңыз* булып та кулланылырга мөмкин: Бойырыңыз, әгәр хезмәтеңез бар булса, баш өсте, бойырыңыз, йибәрим, – диде. Бойырың әфәндем [Насыйри, 1898, б. 10] һ.б.

II зат күплек сандагы *-асы*з кушымчалы хикәя фигыль дә шул ук вазифаны үти: ...бу тарафларга хәрәм бойырасыз. ...Рәхим итәсез [Насыйри, 1898, б. 14] һ.б. Күплек сандагы вариант ешрак кулланыла: бу йәтимгә шәфқать итә күреңез, бойырыңыз, һәр ни кирәк булса, китерәйем. Бу бәндәңезгә бәйан қыйла күреңез, бойырыңыз, назниным, рәхим итә күреңез, қабып қараңыз [Насыйри, 1898, б. 26]; Башка нәрсәдән ғәп орманыз [Насыйри, 1898, б. 26] һ.б.

Дәрәҗәсе белән, яше-эше белән түбәнрәк торган кешеләргә мөрәҗәгать итү, эш кушу, боеру, гадәттә, кушымчасы булмаган боерык фигыль белән башкарыла: Бу кич кибетеңдә қал, бар, бер қапчық кибәк китер, күр, хәлфә пешермәк ничек булыр. Андан соң падишаһ хәлвәфрушны үзенең йанына чақыртып, берәм-берәм сорады: – Бу һәм бер ғәҗәб бер қыйсса, имеш, безгә тәмам бәйан қыйл, – диде... [Насыйри, 1898, б. 35] һ.б.

Эшкә өндәү, боеру-кушуны берникадәр йомшартырга кирәк булганда, бу төр җөмләләрдә, мәгънә эчтәлегендә эмоциональ төсмере булган сүзләр кулланыла: Хәлвәфруш: Йә шәйех, ләтыйф wә кәрәм бойырыб хатамызны ғафу қыйл, – дип ғозер wә нийаз иткәч, Әбуғалисина: – Ғафу қыйлдым, җаным, үзең бәхил бул, – дип, бер-берсе белән қочақлашып-күрешеп, ...И җанымның җаны, бу серне остазыма сөйләгәнем бар, ... солтаным, сабыр ит, дийүр иде, ... әдәп белән утыр, безнең ризалығымызны күзлә [Насыйри, 1898, б. 47] һ.б.

К. Насыйри әхлак вә тәрбия яисә теге яки бу һөнәргә өйрәтү максатыннан чыгып язылган күп кенә хезмәтләрен «углан»га эндәшеп, аңа мөрәҗәгать итеп, эшкә өндәү, һөнәрле булу – бәхетле булу дигән фикерне үткәреп яза. Бу төр язмаларда күп кенә җөмләләр төрле күрсәткечле боерык фигыльгә тәмамлана, әмма кушымчасыз боерык фигыль ешрак кабатлана. «Әхляк рисәләсе»ндә (1881): Әй ғазиз бала әгяһ бул. Адәмгә иң әүwәл бигрәк кирәк, бигрәк лязем нәрсә ғыйлемдер. Wә ғыйлем дигәнемез, белмәгән нәрсәне үгрәнеп wә сорашып белмәкдер... [Насыйри, 1975, б. 102].

«Кабуснамә тәрҗәмәсе»ндә (1882): И уғыл, ...Әгәр күңелләргә әсәрле сүз әйтмәк теләсәң, үз сүзеңне әйт, ғайре шағыйрьләрнең сүзе

булмасын, яғни һәр сүзне әйтсәң, үз фикереңне чығарып әйт,... Имде, и уғыл!.. [Насыйри, 1975, б. 63] һ.б.

К. Насыйриның дини-дидактик әсәрләрендә боерык фигыльнең *-гыл* кушымчасы белән кулланылуы да күзәтелә: ...Ата-ананың wә остазларның хақы бик зурдыр. Ата-ананы рәнҗеткән кеше оҗмахқа кермәс, дигән сүз бар. Һәр заман йаман холықлардан wә йаwыз фиғыльләрдән бик сақлан… [Насыйри, 1881, б. 6].

К. Насыйриның «Мәнафигъ әгъза вә канун сыйххәт» (1893) дигән хезмәтенең күп кенә бүлекләре *белгел* дип башлана: Белгел ки, сөйяк бәдәндә булған әҗзәнең иң қатырағыдыр – wә ул сөйәкдән һәйкәл wә сурәт хасил булыр [Насыйри, 1893, б. 42]; Белгел ки, муйынның алдағы тарафында тире астында буғаз диерләр, буғазның йуқары башы хәнҗәре аталыр… [Насыйри, 1893, б. 44].

Шулай итеп, боерык фигыльнең К. Насыйри хезмәтләрендә ни рәвешле чагылыш табуын карап үткәч, кыскача гына болай дип нәтиҗә ясарга мөмкин: нуль формалы боерык фигыль барлык жанр-стильдә язылган текстларда да актив кулланыла. *-ың, -ыңыз* кушымчалы боерык фигыль, берникадәр үтенү-хөрмәтләү төсмере белән, әхлак-тәрбиягә өндәп языла торган дини-дидактик хезмәтләрдә *-гайсән,* ә сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә *-асыз* (кәрам боерасыз) формалары белән чиратлаша, ә *-гыл* кушамчалысы, киресенчә, катгый итеп үтәлергә тиешлекне белдереп әйткәндә (язганда) файдаланыла.

Боерык фигыльнең III заты, барлык төрки телләрдәге кебек үк [СИГТЯ, 1988, с. 345], татар телендә дә *-сын, -сыннар* формасы белән белдерелә. Мәгълүм булганча, әлеге форма күп төрле мәгънәләр белән кулланыла ала [Юлдашев, 1965, б. 212, Юсупов, 2004, с. 470–473]. Өйрәнелә торган чорда язылган текстларда III зат боерык фигыле барлык мәгънәләре дә чагылыш таба. Әмма матур әдәбият стиленең жанрларында, әлеге фигыль, үзенең катгый боеруны белдерә торган төп мәгънәсе белән бергә, *Алла сакласын*, *Алла насыйп әйләсен*, *Алла насыйп итсен*, *хәерле булсын* һ.б. кебек, үтенү-ышану, теләү-гозерләү мәгънәләре белән ешрак кабатлана. «Кырык вәзир» кыйссасында: Йә йегет, синең өчен күп доға қылдым, бар, кит, ахирәтең хәйерле булсын [Насыйри, 1975, б. 232]; И патша, син ул кешегә бу қадәр хөрмәт итәсең, әмма Аллаһ Тәғалә сақласын, ул кеше халық арасында патшаның йоға торған аwыруы бар дип сөйләп йөри [Насыйри, 1975, б. 232]. «Кырык вәзир» кыйссасында *-сын* формасы тагын а) шарт фигыль мәгънәсендә; ә) билгесез киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсендә;

б) сүзтезмәләрдә файдаланыла: Дөньяның кирәк патша булсын, кирәк фәкыйрь булсын, һичкемгә вафасы юкдыр [Насыйри, 1975, б. 230] һ.б.; Инде атаңа сөйләрмен, һәр санының, қолағыңача итеп тиреңне тунасын [Насыйри, 1975, б. 224].

К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда да боерык фигыльнең III заты шушы ук мәгънәләре белән кулланыла, әмма бу әсәрдә әлеге форма тагын бер үзенчәлекле вазифа үти. Билгеле булганча, автор бер бүлектән икенче бүлеккә күчкән вакытта, гадәттә, түбәндәге тәртиптә төзелгән җөмләләрдән файдалана: Инде болар эзли торсын, без килдек Әбуғалисина wә Әбелхарис хикәйәтенә [Насыйри, 1974, б. 214]; Бәс, бу илчеләр Саба шәһәренә кичеп бара торсыннар, без килдек Саба вилайәтендә булған мажараға [Насыйри, 1974, б. 219-220]. Аңлашылганча, бу типтагы җөмләләрдәге *-сын, -сынлар* (транскрипцияләгәндә *-сыннар*), хикәяләүне алып баруда билгеле бер штамп вазифасын үти һәм башка формалар белән дә алмаштырыла ала: Бу арада Әбелхарис қыйссасы тәмам булып, без киләйек мақсуд асылы булған Әбүғалисина кыйссасына [Насыйри, 1974, б. 225] һ.б.

Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, өйрәнелә торган чорда язылган текстларда, берсе икенчесен алмаштырып, боерык фигыльнең барлык төре дә файдаланыла, әмма нуль формалы боерык фигыльнең ешрак кабатлануы күзәтелә. Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда да бу үзенчәлек дәвам ителә: ...Көндез эшлә wә кәсеб ит, әмма кич хәләлең белән теләгәнчә зәwык wә сафа да бул, ...имде мәне ал сохбәтемдән, күб файдалар алырсән, ...әгәр минем сүземә ышанмасаң, бер җомғаға қайтармақ ихтыйары белән ал, ...сәңа бер сүзем бар, әйтим, аңлаб, аның белән эш қыйл, әгәр дә өч өлеш файда қыйлмасаң, мәне ийәмә қайтарыб бир [Фәизхан, 1886, б. 5] һ.б. Ялыну-ялвару, өмет итүле боеру-теләк мәгънәсе *-әсәң, -гайсән* кушымчалы фигыль белән белдерелә: Әй, Барый Тәғалә, кямил мәрхәмәтеңә йалынырмән ки, Тутыйны тергезәсәң [Фәизхан, 1891, б. 13]; ...Хақ сөбхана wә тәғалә, мақсудларын хасил қылғайсән [Фәизхан, 1891, б. 45] һ.б.

Балалар өчен язылган яисә тәрҗемә ителгән кайбер текстларда *-гыл* формасы вәгазьләү-үгетләү өчен уңайлы-табигый бер чара буларак файдаланыла, нуль күрсәткече белән чиратлаша. Т. Яхинның «Тәгълимел-әдәб-иләл-вәләд – Балалар өчен әдәб гыйлеме» дигән хезмәтендә (1898): Әй уғыл, белгел падишаһның итағате асыл дин илә сабит кәлмеш [Яхин, 1898, б. 4]; ...Белгел ки, һөнәр илән мақтанмақ, нәсәб илән мақтанмакдан йахшырақдыр, имде һөнәр артдырырға

иҗтиһад қыйл, чөнки һөнәрсез кешенең беркемгә дә файдасы булмас, бел ки һөнәрсез кеше йимеше улмаған ағач кебекдер... [Яхин, 1898, б. 10–11] һ.б.

Татар прозасында хикәяләүнең икенче төрен башлаучы М. Акъегет белән З. Бигиев романнарында да хикәяләүне алып баруда нуль формалы боерык фигыльләр ешрак кулланыла, үзара сөйләшү хикәяләүне җанландыра. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә (1886): – Әй син, Сибғатулла, сине үләндермәк кәрәк – диде менла Ғали... – Тап қыз – жаwап бирде Сибғатулла әфәнде... [Акъегет, 1886, б. 13]; Сөйлә, күпме айда табасың [Акъегет, 1886, б. 71], ...Сән анчақ абыстай, башқода бул [Акъегет, 1886, б. 74] һ.б.

*-гыл* кушымчалы боеру фигыле бер затка үтенү белән мөрәҗәгать иткәндә файдаланыла: Абыстай, риҗа идәрмән, менла Хисаметдин шәһәре йитешенчәйә дәк бәне гизләгел, Алла разый улсын [Акъегет, 1886, б. 58].

*-ың* кушымчалы боерык фигыль, традицияне дәвам итәрәк, берничә тыңлаучыга мөрәҗәгать итү чарасы булып тора: Бу җаwапны ишетер-ишетмәс Бикбулат менла һәм шәкертләре қычқырышып: Бақың, бақың, йаман эшне үзе дә инкяр итмәйүр. Һай залим! [Акъегет, 1886, б. 16]. Әлеге форма белән көчле үтенү белдерелә: ...Алла өчен бақың, риҗа идәрем [Акъегет, 1886, б. 21]. Шул ук мәгънәдә *-ыңыз* формасы файдаланыла: Бән дийүрем, әгәр бәхәсләшсәңез, әдәпчә сөйләшеңез, йухса башқа әхwәлдән сөйләңез, бунда әдәбсезлек, бәхәс йире дәгел [Акъегет, 1886, б. 18] һ.б. *-ыңыз* кушымчалы фигыль авторның укучысына эндәшү өчен дә уңай чара буларак файдаланыла: Фикереңезлә ахшам wақытларыны тасаувыр итеңез, уқуҗылар [Акъегет, 1886, б. 40]; Бойырың, бер көн әүwәл, йәғни шинбә көнге маҗаралара диққать идәлем [Акъегет, 1886, б. 54] һ.б. Гозер белән килгәндә дә, бер-берсенә хөрмәтләп эндәшкәндә дә персонажлар шул ук формадагы боерык фигыльне куллана: – Безгә лотыф идеб, башқода булсаңыз иде, абыстай, үләнмәк эстимез, Ғаббас ағаның қызыны сорасаңыз, бөйек мәрхәмәтеңездән булур иде [Акъегет, 1886, б. 48] һ.б.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында *-сын* кушымчалы III зат боерык фигыльләре Алла исеме белән бәйле тезмәләрдә үтенү мәгънәсе белән файдаланыла: Хәйерле улсын, Алла бойырса, без бу эшне қабул итәмез [Акъегет, 1886, б. 48] һ.б. *-сын* кушымчалы фигыль кирәклек, тиешлекне белдергән мәгънәләрне дә белдерә: Диде ки, миллионлар илә русларым бәңа бер уғлымдан бәһаледер, мәйдана

ҡуйдығым исляхат уғылым тарафыңдан бозылса, русларым хәрабәте халә кәлмәсен [Акъегет, 1886, б. 31] һ.б.

З. Бигиев әсәрләрендә дә боерык фигыльнең нуль форма һәм *-ың* күрсәткечле төрләре, нигездә, шул ук тәртип белән бара: катгый итеп эш кушарга кирәк булганда боерык фигыльнең кушымчасыз төренә, билгеле бер дәрәҗәдә хөрмәт күрсәтү белән яисә берничә кешегә берьюлы эндәшергә кирәк булганда *-ыңыз* формалысына мөрәҗәгать ителә. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында (1887): Муса әфәнде: «Бар, исемене белеп кәл», – дидекендә, хадим чығып кәтде [Бигиев, 1991, б. 224]. ...Ниғмәтулла әфәнде: «Бераз сабыр ҡыйлыңыз, ат йигәргә ҡуштырайым, ат илә ҡайтырсыз», – диде [Бигиев, 1991, б. 225] һ.б.

Бу әсәрдә, традицияне дәвам итәрәк, *-әсез (-әсезлә*р) кушымчалы II зат күплек сандагы хикәя фигыль дә хөрмәтләп эндәшүле боеру вазифасын үти: ...кәрәм бойырып кәләсез [Бигиев, 1991, б. 223]; ...Кәрәм бойырасыз, – дип йирләрендән торып, ...бүген унбер сәғатьдә безгә кәләсезләр [Бигиев, 1991, б. 231].

«Гөнаһе кәбаир» романында (1890): ...бу әманәтләрне уғылыма тапшыр wә сәламләремезне әйт [Бигиев, 1890, б. 259]; ...Җә кәл, нә уқыйсың, китапларың ҡайда? Кәл! [Бигиев, 1890, б. 260] һ.б. *-сана* кисәкчәсе белән үтенү белдерелә торган боеру барлыкка килә: ...баланы ҡулыңа тотып торсана [Бигиев, 1890, б. 263] һ.б.

Ике яки берничә кешегә мөрәҗәгать ителгәндә нуль формасы *-ыңыз* кушымчасы белән чиратлаша: ...Уғылыма һәр ҡайумыздан сәлам уқы, икеңез йахшы дуст улып утырыңыз, ...ғомереңезне бушқа, йилгә үткәрмәңез, ...тәғзыйм вәтәкрим ҡыйлыңыз [Бигиев, 1991, б. 256] һ.б. Бу кушымча бер үк вакытта хөрмәтләп эндәшүне дә аңлата.

III зат боеру фигыле *-сын, -сүн* кушымчасы белән бирелә:... Аллаһе тәбарәкә wә тәғалә сезләрә wә безләрә сәламәтлекләр вireп, көн бә көн мәхәббәтләремезне зийадә әйләсен, амин [Бигиев, 1991, б. 235]; Аллаһе тәбарәкә wә тәғалә Муса әфәнденең һәм кәләше Хәдичә туташның ғомерләрен озын ҡыйлып, мәхәббәтләрене көн бә көн зийада әйләсүн [Бигиев, 1991, б. 249] һ.б. Бу әсәрдә бер-ике мәртәбә *-сын* кушымчалы фигыль сөйләүченең, тыңлаучы аркылы, гаиб затка эш кушуны аңлата торган үзенең төп мәгънәсе белән дә файдаланыла: ...зарар йуқ, керсен, күстәреңез [Бигиев, 1991, б. 244] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында да III зат боерык фигыленең кулланылышы шул ук тәртип белән бара: ...Аллаһ кийем wә байлық вирсен [Бигиев, 1991, б. 255]; ...Аллаһе тәбарәкә wә тәғалә

сәфәреңези мөбәрәк әйләсүн [Бигиев, 1991, б. 256] һ.б. Шарт фигыль мәгънәсен алып килә: ...Растуфда тиҗарәт wә хезмәт идән кемсәмез қайтып кәлсә, эстәр йәшь улсын, эстәр қарт улсын, һәр wақытда дин йулында улып, хәрам wә мәхруһатдан иҗтинаб қыйлып, биш wақыт намазым мәсҗедә кәлеп, җәмәғатьлә әда қыйлалар [Бигиев, 1991, б. 255] һ.б.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә (1898) боерык фигыльләр файдаланылмый диярлек, чөнки диалогик сөйләм кулланылмый. Беренче заттан бирелә торган өзекләрдә *-сән* кушымчалы III зат хикәя фигыльнең боерулы-изге теләк мәгънәсе белән файдаланылуы күзәтелә: Аллаһы Тәғалә бөйектер wә бездән мәрхәмәтледер. Сәңа дөньйа wә ахирәттә сәғадәт насыйп итсен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267]; ...Аллаһы Тәғалә бу кеби кемсәнәләрне зийадә итсен! [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 279]. Авторның «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә (1903), персонажларның кара-каршы сөйләшүләре аз булганга, боерык фигыльләре дә сирәк күзәтелә: ...Исемеңне йазып бир әле, мулла [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 320]; ...рәхмәтләрең күләгәсендә җәмғы әйлә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 324]. Хөрмәт белән әйтелергә тиешле урыннарда *-сын* кушымчалы хикәя фигыльнең теләк-боеру мәгънәсе белән кулланылуы күзәтелә: ...Бичара, Алла рәхмәтендә улсын [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 329]; ...Аллаһы Тәғалә сәңа озын ғомер бирсен [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 341].

Р. Фәхретдиннең «Нәсыйхәт. Олуглар вә бөекләр өчен. Гыйлем әхлякдан тукызынчы җөзьә» хезмәте укучыга вәгазь-нәсыйхәт бирү низамында, укучыга эндәшеп языла һәм эзлекле булып, II зат күплек сандагы *-ыңыз* формалы боерык фигыль генә кулланыла: ...Изге хатын дөньйа тереклегеңдә иң қуәтле бер тайаныч, усал хатын адәм уғылы өчен олуғ бер бәладер. Шуның өчен алыначақ хатынларның, кирәк бай wә кирәк фәқыйрь улсын, хөрмәтле ғаиләләрдән эзләңез, раст сүзле wә йахшы күңеллеләрне табарға тырышыңыз, буның өчен, хатынлар, башқодалар сүзенә алданмай, бәлки үз күңел wә ғақылыңыз илә гүзәл фикер әйләңез. [Фәхретдин, 1911, б. 3–4] һ.б.

«Асар» хезмәтендә хатлар стилендә язылган текстларда II зат күплек сандагы *-асыз* кушымчалы хикәя фигыльнең боерулы теләкне бирү үзенчәлеге эзлеклерәк саклана. Эстәрлебаш мәдрәсәсе мөдәррисе Нигъматулла хәзрәтнең хаҗга киткән улы Хариска язган хатында түбәндәге юллар бар: Саирләренә ғасәл вирәсез халегезә муафиқ wә

һәм мелла Ғазизулла һәм Қамаледдин мәхдүмә ғасәлдән вирәсез wә һәм мелла Рәхмәтуллаға доға сәлям, анлара ғасәлдән вирәсез, һәр қаюларыңдан доға өмидләремез [Фәхретдин, 1904, б. 80–82] һ.б.

Әлеге үзенчәлек Ф. Әмирханның бер хатында чагылып китә: Ғарыз идәм: ушу тиз wақытта Қазанға қайтып китмәкеңез лязем уладыр. Хәзрәтдән өч-дүрт көнгә изен алып киләсез... [Әмирхан, 1986, б. 225]. Бу очракларда *-асыз* формасының нәзакәтле үтенүне белдерү мәгънәсе белән файдаланылуы аңлашыла.

Ф. Кәриминең сәнгатьле проза әсәрләрендә боерык фигыльнең кулланылышында, асылда, язма традиция дәвам ителә, әмма *-ың* формасының кулланылуы күренми, *-ыңыз* формасы кайбер әсәрләрдә халыкчан-сөйләмә *-ыгыз* күрсәткече белән белдерелә башлый. «Шәкерт илә студент» әсәрендә (1899) хәзрәтнең «мөселман кийеме кисәңез йахшы булыр» дигән киңәшенә каршы, аны тыңлаучы, «хәзрәт, бер үк ғафу итегез» дип җавап бирә. Шәкертләрнең наданлыгына каршы куелып сурәтләнә торган студент *-ыгыз* кушымчалы боерык фигыльне файдалана:... Теләсәгез, минем сүземне тәҗрибә итеп қарағыз. Сез әүwәл бик йахшы итеп үз телегезнең сарыф нәхү қағыйдәләрен уқығыз... [Кәрими, 1996, б. 46]. Әсәрдә хикәяләүне алып баручы да шул ук форманы куллана: ...безем йанға чәй эчәргә рәхим итегез, –дидем [Кәрими, 1996, б. 52]. «Нуретдин хәлфә» хикәясендә (1900) мондый бүленеш күзәтелми, ягъни автор тарафыннан уңай итеп тасвирлана торган «йазу җәһәте кимчелекле булса да, уқу җәһәте бәк йахшы булған, ...ачық йөзле, туғры сүзле бер мужик» Гайнетдинов, гамәлне алып баруда укырга кирәкми дигән кешеләргә, «...сез – үзеңез белгәнчә йөреңез, мин үзем белгәнчә йөрим... дип җаваплана» [Кәрими, 1996, б. 78]. Авторның «Морза кызы Фатыйма» әсәрендә (1901) *-ыңыз* формалы боерык фигыльнең кулланылышы үзенчәлекле. Морза булмаган чәчкә үстерүче Мостафа, аерым кешегә хөрмәтләп эндәшү өчен, *-ыңыз* кушымчалы фигыльне файдалана: ...Җаным, қорбаныңыз улайым, Аллаһ өчен туғрысыны сөйләңез [Кәрими, 1911, б. 85]; ...айақларыңызы үпәйем, ғафу итеңез [Кәрими, 1911, б. 3-4] һ.б. Морза кызы Фатыйма нуль формалы фигыльне куллана: ...Чәчәкләрең бик гүзәл икән, бәңа бер букет йасап бир – диде [Кәрими, 1911, б. 86]. Аңлашылганча, *-ыңыз* кушымчалы боерык фигыльнең кулланылышы сурәтләү чарасы буларак файдаланыла башлый.

Нуль форма кайбер хикәяләрдә *-сана* һәм *әле* кебек кисәкчәләр белән бергә кулланыла. «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә: Йә,

Салих бабай, шул йәшь wақытта кичергән хәлләреңне безгә сөйләсәнә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 223]; Тукта әле, Салих бабай, [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 226]

Ф. Кәрими әсәрләрендә дә *-сын* күрсәткечле боерык фигыльнең, нигездә, боерулы теләк мәгънәсендә кулланылуы дәвам итеңә: Алла рәхмәт итсен үзенә, менә wафат булған әбийегез шул иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 229]; ...Алла истиқамәт насыйп әйләсен [Кәрими, 1996, б. 35] һ.б. Шарт фигыль мәгънәсендә файдаланыла: Хәзрәт қолақны бора, суфый абзый илә қазый хақлы булсын, хақсыз булсын, һәр көн сыртқа чыбық суғалар, иптәшләр көлә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 236] һ.б. Киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсендә: Алар ғыйлемсез, һөнәрсез, барысы да йарлы булса, зәкятны ничек бирсен? Ғошерне қайдан алып бирсен? Ул үз тамағын туйдыра алмас [Кәрими, 1996, б. 50] һ.б.

Мөмкинлек яки мөмкин булмау мәгънәсендә: Ул иген игүнең йәки сату итүнең ниндәйен мәктәбе булсын? Анда ни уқысын? [Кәрими, 1996, б. 77]; Ғомәр морзаның қаршы киләчәгеннән wә аның аты өркәчәгеннән аның нә хәбәре улсын? [Кәрими, 1996, б. 89] һ.б. Сөйләшүче аркылы эш кушу, сөйләүченең теләгән җиткерү мәгънәсендә: Бәдри әби сәне озатсын [Кәрими, 1996, б. 101] һ.б. Кирәклек, тиешлек мәгънәсендә: һөнәрле, мәғрифәтле булсыннар, байысыннар – аннан соң зәкят, фитра бирергә нәсихәт итәргә кирәк [Кәрими, 1996, б. 50] һ.б.

Аңлашылганча, *-сын* кушымчалы боерык фигыль Ф. Кәрими әсәрләрендә шактый актив һәм, үзенең төп мәгънәсе белән куллануына караганда, күчерелмә мәгънәләре белән ешрак кабатлана, персонажларның үзара һәм аларга карата авторның төрле мәнәсәбәтен тасвир итә ала торган сурәтләү чарасы буларак файдаланыла.

Боерык фигыль формаларын куллануда мәгърифәтчеләр иҗатында башланган бу үзенчәлек классик әдипләр иҗатында да дәвам итеңә. Нуль формалы боерык фигыльнең барлык һәм юклык төре яратып кулланыла. Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт...» хикәясендә (1899): ...Алай сөйләмә, ...мәдрәсәгә тел тийермә, атам [Исхакый, 1998, б. 32]; ...бик йахшы қунақ ит [Исхакый, 1998, б. 35] һ.б.

Нуль формалы фигыль *-сана* кәсәкчәсе белән үтенелү боеруны белдерә: ...Баланы надан қалдыруда һич файда йуқ, зинһар җибәриксәнә [Исхакый, 1998, б. 31]; ...қарасана, Рәхимә абыстай... [Исхакый, 1998, б. 41] һ.б. Персонажлар сөйләмендә күпчелеккә мөрәҗәгать ителгәндә *-ыңыз, -ыгыз* кушымчалы фигыльләр чиратлаштырыла: ...хуш, сағ

улыгыз [Исхакый, 1998, б. 39]; …әйдә, әйдәгез, рәхим итегез [Исхакый, 1998, б. 46] һ.б. Драма әсәрләрендә дә вакыйгаларның барышы боерык фигыльнең кушымчасыз төренә нигезләнә, ләкин язма-традицион формалар да тулаем инкяр ителми. Әлеге формалар, билгеле бер дәрәҗәдә, персонажны характерлау чарасы буларак сайлана дип әйтеп булмый, чөнки алар берсе икенчесен алмаштырып файдаланыла.

*-сен* кушымчалы III зат боерык фигыле, асылда, Аллаһе Тәгаләгә өмет баглау юнәлешендә: Аллаһе Тәгалә оҗмах сарайлары насыйп әйләсен [Исхакый, 1998, б. 35]; Аллаһе тәгалә тәүфыйк, бәхет биреп, дөньйа wә ахирәт, шатлыклы гомерләр насыйп әйләсен [Исхакый, 1998, б. 39] һ.б.

Г. Ибраһимовның да башлангыч чор иҗатында боерык фигыльнең нуль формасын *-ыңыз* күрсәткече белән чиратлаштырып файдалануы күзәтелә. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә (1907): Әйдә, рәхим идеңез, хуш килдеңез, рәхим идеңез [Ибраһимов, 1974, б. 402]; Угылым, саг бул, укы, тырыш итагать ит! [Ибраһимов, 1974, б. 403]. «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» әсәрендә (1909) үтенүле боеру *-асез* кушымчалы фигыль белән белдерелә: ...бу кич сәгать җидедә минем фатирыма рәхим итәсез [Ибраһимов, 1974, б. 485]; Гафу итүне үтенү *-ыңыз* кушымчасы белән күрсәтелә: ...гафу идеңез [Ибраһимов, 1974, б. 489]. Хикәяләрдән аермалы буларак, бу очракта, боерык фигыльнең төрле формаларын куллану, персонажның характерын сурәтләү чарасы буларак файдалана булса кирәк.

*-сын* кушымчалы III зат боерык фигыль, традицияне дәвам итәрәк, үтенүле боеру мәгънәсен белдерә: ...Дөньйа сездән гыйбрәт алсын [Ибраһимов, 1974, б. 472] һ.б. Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» әсәрендә (1912) *-сын* кушымчалы фигыль явызлык теләү, каргау белдерү вазифасы белән кулланыла: Атайга йазу йук, атайдан сорау йук. Тот та шундый эшләр кыйл. Әйтмичә йугал. Йугалсын... бетсен... мәңгегә кадалсын... Йөзенә төкерермен ...кяфернең [Ибраһимов, 1975, б. 52] һ.б.

Боерык фигыльнең төрле күрсәткечен билгеле бер максатка яраштырып файдалану Ф. Әмирхан әсәрләрендә тагын да сиземлерәк чагыла. Бер үк әсәрнең тар контекстында әлеге кушымчаларның чиратлашып кулланылуы, аларның вазифаларын ачыграк күзалларга ярдәм итә. Мәсәлән, «Танымаганлыктан таныштык» хикәясендә: Рәхим итегез, – дидем. ...Студент ...миңа мөрәҗәгать итеп, русча – Гафу итеңез, бу гәзитә нинди телдә йазылган? – дип сорады [Әмирхан,

1984, б. 62]. Русча әйтелгән сүзне автор югары стильдә бирергә кирәк дип санаган булса кирәк, әмма алга таба персонажлар берсе икенчесе белән, башлыча, халыкчан вариант белән аралашалар: Алай булса, сез, рәхим итеп, мине белештерегез [Әмирхан, 1909, б. 17]; Эчегез тизрәк, булмаса қоры қаласыз [Әмирхан, 1909, б. 19] һ.б.

Ф. Әмирхан әсәрләрендә традицион-язма һәм халыкчан-сөйләмә вариантларның чиратлашуы «Хәят» повесте һәм «Кадерле минутлар» хикәясендә дә шундый ук юнәлештә дәвам итә, ягъни берникадәр дәрәҗәдәге рәсми-югары тондагы сөйләмдә *-ңыз,* ә инде гадиләшә баруны тасвирларга кирәк булганда *-гыз* формасы файдаланыла. Мәсәлән, «Хәят»та: Үтенәм, безне үз халебездә қалдырыңыз [Әмирхан, 1911, б. 15]. Урыны-урыны белән бу формантлар чиратлашып та китә: Ишетегез әле, сез әүwәлләрдә бик матур җырлыйдыр идегез. Җырлаңыз әле берәр нәрсә, – диде [Әмирхан, 1911, б. 15]. «Кадерле минутлар» хикәясендә: Қарағыз әле Қабан тирәсенең күренешен [Әмирхан, 1912, б. 8]; ...Мөмкин булса, сөйләңез башқаларын да [Әмирхан, 1912, б. 17] һ.б. Алга таба халыкчан вариант кына файдаланыла [Баширова, 1988, б. 112–116].

Беренче драма әсәрләрендә, асылда, боерык фигыльнең кушымчасыз төре файдаланыла. Г. Ильясиның «Бичара кыз» драмасы (1887): Маһитап. Әбийем, җаным, кил, утыр ...мин синнән бер сүз сорыйм. ...Сәхибә. Сора, қызым... [Татар әдәбияты, 1957, б. 556]. Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» (1888) драмасында: Хәлимә. ...Хәлимә қайда дип сорасалар, пич башында йата, башы ағырып дип әйт [Татар әдәбияты, 1957, б. 575] һ.б. Әмма бу авторның «Морад Сәлимов» (1905) драмасында, Морад Сәлимовның укымышлы кеше икәнлеген күрсәтү максатыннан, боерык фигыльнең традицион формасына да мөрәҗәгать ителә: Морад. Хәйерле булсын, берәр урын булмасмы, күз-қолақ булыңыз [Татар әдәбияты, 1957, б. 594]; ...Хуш килдеңез, бай, түргә узыңыз [Татар әдәбияты, 1957, б. 596] һ.б. «Комедия Чистайда» (1895) әсәрендә *-сана* кисәкчәле боерык фигыльләр кабатлана: Әфләтун. ...әйтсәнә миңа, Хөсни, ул көн буе ни эшли, ни қыла? [Татар әдәбияты, 1957, б. 637]; Хәйри. Хөсни, барсана, безгә чәй китерсәнә, азрақ эчем пошқалый... барсана, бар... [Татар әдәбияты, 1957, б. 642]. Әлеге драмада бер мәртәбә II зат күплек сандагы *-асыз* кушымчалы хикәя фигыль дә үтенүле боеруны белдерә: Әфләтун. Хәйри абыстай, мин сезгә шул бер ғөзер берлән килдем. ...Әгәр мөмкин булса, бүген эшне бетереп җибәрәсез... [Татар әдәбияты, 1957, б. 638].

Аңлашылганча, *-сын (-сун), -сыннар (-сунлар)* формалы боерык фигыль үзенең барлык мәгънәләре белән драма әсәрләрендә дә киң кулланылыш ала.

*Кыскача нәтиҗәләр.* XIX гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән төрле жанр-стильдәге текстларда II һәм III зат боеру наклонениесе (императив, боерык фигыль) нуль форма, *-гыл, -ың, -ыңыз ,-асан, -санә, -саң, -ыгыз, -сын (-сун), -сыннар (-сунлар)* формалары белән белдерелә. (Татар телен өйрәнеп язылган беренче грамматикаларда *-гыл* кушымчасы искә алынмый.) Шулай итеп, боерык фигыль, өйрәнелә торган чорда, угыз һәм кыпчак телләренә хас булган ике әдәби тел нормасында кулланыла, графо-орфографик, морфологик һәм синтаксик вариантлылык хасил итә.

Графо-орфографик дигәндә, боеру наклонениесен белдерә торган кушымчаларның төрлечә язылышы истә тотыла: традицион-язма *-ыңыз* формасы белән бергә, халыкчан-сөйләмә *-ыгыз* варианты да гамәлгә куела һәм активлаша.

Морфологик вариантлылык дигәндә, әлеге фигыльнең төрле төсмерләр белән эшкә кушу, эштән тыю,боеру, өндәү кебек категориаль мәгънә белдерүе белән бергә, тагын кирәклек, тиешлек, мөмкинлек мәгънәләрен белдереп кулланыла алуы истә тотыла.

Синтаксик вариантлылык дигәндә, боерык фигыльнең мәгънә төсмерләренең төрле лексик чаралар белән ныгытылуы һәм тотрыклы сүз тезмәләрендә кулланылуы истә тотыла.

Әлеге формаларның файдалануында, билгеле бер дәрәҗәдә, эш бүленеше күзәтелә, ягъни төрле жанр-стильдә язылган текстларда алар төрле ешлыкта кабатлана һәм хронологиягә бәйле рәвештә дә үзләренең активлык һәм пассивлыкларын үзгәртәләр, әлеге нигездә, функциональ-стилистик вариантлылык барлыкка килә: *-саң* кушымчалы боерык фигыль, башлыча, Ә. Уразаев-Кормаши кыйссаларының тезмә өлешендә кулланыла. К. Насыйри, Т. Яхин һ.б. тарафыннан язылган дини-этик һәм дөньяви-дидактик хезмәтләрдә нуль форма, *-ың* күрсәткечле, билгеле бер дәрәҗәдә катгыйлыкны аңлата торган, *-гыл* күрсәткечле боерык фигыльләре эзлекле булып кабатлана.

Мәгърифәтче һәм классик әдипләр иҗатында боерык фигыльнең нуль форма һәм *-ың, -ыңыз* күрсәткечлесе актив кулланыла, авторның укучысына эндәшүен һәм персонажларның үзара сөйләшүен бирүдә уңай бер чара булып тора, образ барлыкка китерү чарасы буларак та файдаланыла, *-ыгыз* формасы өстенлек ала бара һәм норма буларак

ныгый. Боерык фигыльнең *-сын* формалысы, хәзерге татар әдәби телендәге һәм җанлы сөйләшләрдәге кебек үк, өйрәнелә торган чорда язылган текстларда да күп төрле вазифа башкара.

*Теләк фигыль.* Хәзерге татар әдәби телендә I зат берлектә *-ый/-и,* I зат күплектә *-ыйк/-ик* кушымчалы, нинди дә булса эш эшләргә теләкне белдерә торган фигыль теләк наклонениесе дип атала. Сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерә торган модальлек дигән функциональ-семантик категориянең бер күрсәткече булган теләк фигыль, әдәби телдә дә, диалектларда да *-гай/-гәй, -гыре/-гере, -кыры/-кере* кушымчалары һәм шулай ук *-асы кил, -асы иде, -рга иде, -ыр иде* һ.б. аналитик формалар белән белдерелә [Тумашева, 2002, б. 154–157; Хисамова, 2006, б. 202–203; Юсупов, 2004, с. 475–501].

Татар телен фән буларак өйрәнеп язылган беренче хезмәтләрдә теләк мәгънәсенең затка мөнәсәбәте һәм аның кушымчалары төрле авторда төрлечә күрсәтелә. Г. Фәезханов «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» китабында (1887): «III зат берлектә (гаиб мөфрәддә) *-сун ла,* III зат күплектә (җәмгъ гаибдә) *-сунлар ла,* II зат берлектә (мөфрәд мөхатәбдә) *-сана,* II зат күплектә (җәмгъ мөхатәбдә) *-саңыз ла,* I зат берлектә (мөфрәд мөтәкәллимдә) *-ыйм ла,* I зат күплектә (җәмгъ мөтәкәллимдә) *-ыйк ла* адәтләре тоташтырыла», дип аңлата [Фәизхан, 1887, б. 25]. Шулай итеп, бу авторда боеру һәм үтенү (теләк) фигыльләре бергә карала.

К. Насыйриның «Әнмүзәҗ» хезмәтендә *алыйм, алайым* дип бирелгән фигыльләр «әмер мөтәкәллим» дип аңлатыла, ягъни I затка (сөйләүчегә) нисбәтле боеру булып аңлашыла. К. Насыйри, Г. Фәезхановтан аермалы буларак, әлеге фигыльнең һәм тар, һәм киң язылышын да әдәби норма итеп күрсәтә [Насыйри, 1975, б. 75].

М. Өметбаевның «Татар нәхүсенең мохтәсары» дәреслегендә исә I зат боерык фигыле булмый дип раслана: «Әмер, яғни бойырмак, бунда беренче вәҗһе, яғни сөйләүче әйтелмәй, әмма әйтеләдер ки II һәм III вәҗһе ки, яғни мохатаб илә ғаибкә». *-гай/-гә*й кушымчалы фигыльне бу автор киләчәк заманның икенче дәрәҗәсе дип бирә [Өметбаев, 1901, б. 28-29].

Билгеле булганча, татар телендәге теләк, боерык һәм ният фигыльләре, 60 нчы елларның ахырларына кадәр диярлек, башка авторларда да аерымланмыйча, бергә каралып килә [Хәзерге татар..., 1965, б. 239–247]. Әлеге мәсьәлә Л. Җәләйнең хезмәтендә аңлатыла,

бу авторда боерык фигыльнең I зат берлек саны *-ыйм/-им,* күплек саны *-ыйк/-к* кушымчалы боерык-теләк дип бирелә [Җәләй, 2000, б. 176–182].

Гомумтюркологик хезмәтләрдә дә теләк фигыльнең кушымчалары, этимологиясе һәм мәгънә белдерү үзенчәлекләре төрле авторда төрлечә бирелә, әмма барысында да *-алем, -алек* формаларының теләк мәгънәсен белдерүе ерак гасырлардан ук традиция булып килүе аңлашыла. Аерым хезмәтләрдә теләк фигыльнең төп күрсәткече дип *-гай* кушымчасы санала. Ләкин бу кушымча хикәя фигыльнең киләчәк заманы буларак та истә тотыла [СИГТЯ, 1988, с. 330, 338].

Башка хезмәтләрдә теләк фигыльнең саф күрсәткечләре дип *-ай* һәм *-але* кушымчалары санала: *-ай* күрсәткече I затның берлек санында, *-але* форматы күплек санында кулланыла дип белдерелә. Әлеге кушымчаларның *-айым, -айын, -алем, -ален, -айың, -алең* һ.б. форматларда төрлечә катлаулана алуына күп сандагы мисаллар китерелә [Благова, 1973, б. 10–25]. А.М. Щербакның хезмәтендә теләк фигыльнең төп күрсәткечләре дип, *-а(й) һәм -га(й)* кушымчалары санала. Тюркологиядә еш кабатлана торган фикергә мөнәсәбәт белдерелеп, *-а(й)* форматының *-га(й)* күрсәткеченең фонетик варианты була алуына шик белдерелә, *-га(й)* кушымчасының *-а(й)* кушымчасына караганда, функциональ-семантик яктан үзенчәлекле һәм активрак булуы нигез итеп алына [Щербак, 1976, б. 184–190].

Иске татар телендә язылган истәлекләрне тикшерүчеләрнең хезмәтләрендә теләк фигыльнең табигате һәм вазифасы өйрәнелә торган текстта ничек итеп файдаланылуына карап анализлана. «Кисекбаш китабы»нда теләк фигыль *-гале, -алым, -айын* формаль күрсәткечләре белән реальләшә, *-алем* күрсәткече ешрак кабатлана, саф теләктән башка тагын иярчен шарт җөмләнең баш җөмләсендә киләчәк заман мәгънәсен, *-айын* кушымчасы I зат берлек санын белдерә. *-гай* формасы бу хезмәттә, сөйләүченең яисә Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры белән киләчәктә эшләнәчәк эшне белдерә торган киләчәк заман хикәя фигыле дип аңлатыла [Ахметгалеева, 1979, б. 94, 98–99].

Алтын Урда чорында язылган әдәби әсәрләрдә теләк наклонениесе берлек санда – *-айын, -айым, -гайын, -им,* күплек санда *-алең, -алым, -галың, -галым, -гам* кушымчалары белән бирелә [Нуриева, 2004, б. 71–72, 123–124, 165, 186, 217–218, 227]. Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» (1310) әсәрендә I зат берлек санда – *-айын/-әйен, -айым,* күплек санда *-алең/-әлең, -али/-әли, -әлек* күрсәткечләре файдаланыла

[Исхакова, 2005, б. 137]. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә файдаланыла торган боеру һәм теләк фигыльләре бергә анализлана [Гайнуллина, 2010, б. 142–152].

XIV гасыр ахыры – XIX йөз башында язылган рәсми дипломатия текстларында боерык-теләк фигыльләренең *-гай, -гай ирде, -а/-ә,* халыкчан-сөйләмә *-ай-ым/-әй-ем,* традицион-архаик *-алук/-әлүк* кушымчалары белән белдерелүе ассызыклана [Хисамова, 1999, б. 381–382, 384, 387].

XVIII гасырда язылган «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе»ндә теләк фигыльнең *-гай* кушымчасы белән белдерелүе һәм аның бер мәртәбә генә кулланылуы искәртелә [Алеева, 1993, с. 64].

XVIII гасыр ахыры – XIX йөз башында иҗат итүче Г. Утыз Имәнинең тезмә әсәрләрендә *-ай/-әй, -айын/-әйен, -алы/-әле, -алым/-алем* формалы синтетик һәм *-гай/-гай ирде, -са ирде/иде, -р ирде/иде* күрсәткечле аналитик төрдәге теләк фигыльләренең актив файдаланылуы барлана һәм тикшерелә [Мухаметрахимова, 1990, с. 13]. XIX гасыр ахырында Ф. Халиди тарафыннан тәрҗемә ителгән «Мең дә бер кичә» хикәятләренең телен өйрәнүче Ф.Ф. Гыйлемшин хезмәтендә, теләк фигыльнең *-айым, -айык, -алык, -алем* формаларында кулланылуы күрсәтелә [Гилемшин, 2001, с. 108].

XVIII гасыр ахыры – XIX йөз башы шагыйре Кол Мөхәммәд иҗатын өйрәнүче Г. Зәйниева *-гай/-гәй, -кай/-кәй* кушымчалы фигыльләр бу авторда, «Кисекбаш китабы»ндагы кебек үк, III зат берлек санда киләчәк заман хикәя фигыль вазифасын үти дип белдерә: Дәхи остаз эшене алға алғай, Ата-ана эше соңға қалса қалғай... Йитенче икрар иткәй кем Хақ Тәғалә. «Кисекбаш китабы»ндагы кебек үк, киләчәктә урнашачак эшнең Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры белән башкарылачагы аңлашыла. Бу авторның поэмаларында *-ың, -ең, -аң* формалы теләк мәгънәсе ачык сизелә торган боерык фигыльләрнең еш кулланылуы ассызыклана [Зәйниева, 2006, б. 90–91].

Р.М. Мирхәев белдерүенә күрә, XIX гасыр ахыры – XX йөз башында, иске татар теленең угызлашкан вариантында иҗат итүче мәгърифәтчеләрнең иҗатында теләк фигыль *-айым/-әйем, -алем/-әлем* кушымчалары белән күрсәтелә [Мирхаев, 2007, с. 105–108]. Б.К. Миңнулин хезмәтендә газета текстларында теләк фигыльнең синтетик: *-ыйм, -ыйк, -айым, -айык* һәм аналитик: *-са иде, булса иде, -макчы бул* формалары белән белдерелүе аңлатыла [Миннуллин, 2012, с. 182–186]. Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, теләк фи-

гыльнең төрле жанр-стильләрдә, аеруча поэзия әсәрләрендә, барлык күрсәткечләре һәм мәгънә төсмерләре белән яратып файдаланылуы аңлашыла.

Ә. Каргалыйның III заттан хикәяләү рәвешендә язылган «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә (1845) теләк фигыльләре I заттан әйтелә торган өзекләр килеп кергән урыннарда гына кулланыла:

*-алем* кушымчалы теләк фигыль: нидәлем бу эшдә тәдбирең нәдер? йидерәлем аңа. Хак ризасы чөн бу кяри идәлем, нәфсемез арзусыны тәрек идәлем, идәлем инсафәйә иханы дин [Каргалый, 1889, б. 4]. Мисаллардан күренгәнчә, теләк фигыль *-алем* күрсәткече белән бирелә һәм берничә кеше бергә сөйләгәндә кулланыла. Диделәр: әйләйәлем имди сәңа васфы хәл [Гайнетдин, 2002, б. 92]. Бер генә кеше сөйләгәндә дә файдаланыла: Диде шәйхә: нә идәлем, әй ғазиз? Нитәлем бу эшдә? ...Диде солтан хатына: сабыр итәлем, ахшамәдәк көтәлем. Нитәлем, әл-хөкме Аллаһы қаза [Гайнетдин, 2002, б. 104]. Әмма бу очракта сөйләүче белән тыңлаучының бер булып теләктә торулары аңлашыла кебек. *-айым* формасы белән бер генә кешенең теләге белдерелә: Диде ахыр ...варайым, шәйехнең айағын үпәйем, ...үләйем [Гайнетдин, 2002, б. 97]. Теләк һәм үтенү мәгънәсе лексик чара һәм ярдәмче фигыле белән белдерелә: Нәфсемез арзусыны тәрек идәлем (нәфсемезнең теләген ташлыйк) [Каргалый, 1889, б. 4].

Һ. Салиховның тормыш чынбарлыгы I заттан тасвирлана торган «Тәэссеф» дигән 18 дүртьюллы шигыренең беренче дүртьюллыгы болай яңгырый: Ғәфләт илә үтте ғөмрем, әй дәриға, нидәйем?! / Дәрдемең дәрманын эстәй қанчруйә нидәйем? / Нәфсе-шәйтан золмыдан кемгә шикәйәт идәйем? / Ғәфләт илә үтте ғөмрем, әй дәриға, нидәйем?! [Татар поэзиясе..., 1992, б. 272–273].

*-айым* кушымчалы теләк фигыль персонаж сөйләме итеп бирелә торган өзекләрдә дә файдаланыла: Бере дийер: «Бән торайым, сән борын йат, / Бәс андыйн сән торырсән, бән йатайым, / Чү! Дошман кәлсә, қанына батайым [Салихов, 1900, б. 17].

Бу авторда теләк фигыльнең башка формалары да файдаланыла, әмма алар *-айым* күрсәткече кебек тезелеп бирелми: Йөзем алда, күңел артда, башым йирдә, күңел шүрдә, / Бәнем тик булмағай бер дә – һидайәт вир бәңа йа Рабб... [Салихов, 1856, б. 8]. Сүз сөрешеннән *-гай* кушымчасының хәзерге-киләчәк заманның юклыгы булган

*-магай* формасы белдерә торган мәгънәдә кулланылуы аңлашыла. Түбәндәге җөмләдә *-алем* кушымчасы файдаланыла: Бу кәз сезгә нәдер чара? Улынмаң шимди әwара, / Киләлем җөмлә бер ара, – һидайәт вир бәңа йа Рабб [Татар поэзиясе..., 1992, б. 271]. *-әлем* күрсәткеченең I зат берлек сандагы теләкне белдерүгә аңлашыла. Бу авторда *-гай* күрсәткечле фигыль кебек үк, *-алем* кушымчалы теләк фигыль дә, Раббыга мөрәҗәгать ителеп, аңарга сыену, үтенү, ышану көтелә торган теләкне белдерә.

Ш. Зәкинең, «Асар»да теркәлгәнчә, «Бән Ходаның бер ғәрибе ғасый wә җафи қолыйым» дип, «Татар поэзиясе антологиясе»ндә һәм М. Гайнетдинов җыентыгында «Игре йуллары қуйубән, туғры йула варасы» дип башлана һәм үзен Ходаның гөнаһлы-җәфалы колы дип санаган, барча начарлыклардан саклану өчен Тәңрегә ялварырга кирәклек сурәтләнә торган шигырендә *-әйем* күрсәткечле теләк фигыль кулланыла: Хәсрәт уты төште, йақты қалбеме әйнелмәҗал, / Нитәйем кем заил улмаз күңлемең бимарасы... [Гайнетдинов, 2002, б. 32]. *-әйем* кушымчалы фигыльнең үкенүле-үтенүле, ялварулы теләкне белдерүгә аңлашыла. «Бақый ғөмерем әһле тәқуалар илән кичсен бәнем...» дигән юлда көчле теләкнең III зат боерык фигыле белән дә бирелүе күренә. «Асар»да бу юл урын алмаган [Татар поэзиясе..., 1992, б. 319, 2002, б. 32]. Шул ук мәгънә *-ем, -ә* кушымчалы теләк фигыльләре белән дә белдерелә: Нитә күңел вирәрем бу дөнйаға, / Нә қадәр йабсам, һаман вәйранадыр... [Татар поэзиясе..., 1992, б. 316]; Нә хуш сәүдә виребсәң бәңа, йа Раббе, / Ғамь илә кичәрем йаз көземдән... [Гайнетдинов, 2002. б. 34]. *-ем* һәм *-а* кушымчалы фигыльләрнең бер үк сүзләр бәйләнешендә, иярчен шарт җөмләләрнең баш җөмләсе булып килә торган позициядә көчле теләкне белдерүе күренә. Иярчен сәбәп җөмләнең баш җөмләсендә дә шундый ук теләк белдерелә: Мән теләрем кем шул қаумең зөмрәсендән улмаға, / Анлара Хақ рәхмәтендән қатрә әқтар әйләде... [Гайнетдинов, 2002, б. 36].

Аерым шигырьләрдә авторның тасвири фикере бу төрдәге фигыльләрне махсус рәвештә кабатлау юлы белән ясала: «Назмы дигәр...» дип башлана торган шигырьдә «эстәрем» (телим) сүзе беренче ике юлда рәттән, аннан соң һәр юл аша килеп, сигез мәртәбә кабатлана: Мәғсыйть рәсмен қуйубән тәғатый нур эстәрем, / Бу фәна милке нидарәм, чөн бәка йорт эстәрәм. (Гөнаһлы-языклы гадәтне ташлап, бер-беремә нур телим, Бу фани милек белән ни эшлим, мәңгелек йорт телим) [Гайнетдинов, 2002, б. 50].

Мисаллардан аңлашылганча, *-ем/-әм* кушымчалы фигыльләрнең һәрдаим булуын теләү мәгънәсе хәзерге-киләчәк заман мәгънәсенә якынлашыла. *-гәй* кушымчалы фигыль дә шул ук мәгънәне белдерә: Чуқ гөнаһ итдем бән ул мәғбудемә бу дөнйада, / Нитә виргәймән җәауабы, хәзрәтенә варасы... [Татар поэзиясе.., б. 319, 2002, б. 32].

Авторның «Эстәсәм галәмдә сәндик йары булгай, булмагай» дип башлана торган шигырендә *-гай/-гәй* кушымчалы фигыльләр, барлык һәм юклык формалары белән, эзлекле рәвештә кабатланып кулланыла: Эстәсәм ғаләмдә сәндик йары булғай, булмағай, / Булса булғай сән кеби ғамьхәвари булғай, булмағай / Ат сәнең астыңдадыр, йөргел бу йирнең хәдден ал, / Нагяһан ул ат сәнең астыңда булғай, булмағай... Шулай итеп, *булгай*, *булмагай* һәм *килгәй*, *килмәгәй* сүзләрендә *-гай, -гәй* формалы фигыльләр кабатланып, хәзерге-киләчәк хикәя фигыль мәгънәсен белдереп, унике мәртәбә файдаланыла [Татар поэзиясе..., б. 317, 2002, б. 39].

Ш. Зәкинең аерым шигырьләрендә *-алем* формалы теләк фигыльләре хәзер үк башкарылырга тиеш теләкне белдереп кулланыла: Вирәлем йуқлыға бу варлығымны, Бәңа бу варлығым әзғас әхлямемдер... (Бирәм бу йуклыкка (үлемгә) бу барлыгымны (яшәвемне), Миңа бу барлыгым саташулы төш кебек) [Гайнетдинов, 2002, б. 37].

Әмма шул ук фигыльләр «Мөнәҗәт» дип башланган шигырьләрдә лексик чаралар белән куәтләнеп, һәрвакытта, эзлекле рәвештә булуы теләнгән, үтенүле, ялварулы теләкне белдерә: Йаратканға йалуаралем, Туғры йул берлә варалем, / Бәладин җан қортаралем, Дишwар улды бәнем халем [Гайнетдинов, 2002, б. 42]. Бу юлларда *бән* сүзе булмаса, *-алем* кушымчасы күплекне белдерә дип тә әйтергә мөмкин булыр иде. Түбәндәге юлларда да шул ук хәл: Чара будыр кем сәңа йалваралем, / Йуқса айруқ қанча руйа вараләм. / Сәндән анчақ эстәрем, шаһым, сәне, / Қортарыйдыр ошбу бәнлекдән бәне [Гайнетдинов, 2002, б. 43–44]. Монда *бән*, *сән* алмашлыклары һәм *-ем* кушымчалы теләк фигыль белән чиратлашып бирелүе *-алем* кушымчасының берлек санда баруын раслый. Әлеге кушымчаның берлек санында гына кулланылуы А.Ф. Йосыупов хезмәтендә дә ассызыклана [Юсупов, 2006, с. 101]. Борынгы төрки телдә I зат күплекне белдерә дип аңлатыла торган *-алем* күрсәткеченең [Благова, 1973, б. 11] берлектә файдаланылуы, Ш. Зәки иҗатының үзенчәлегенә бәйле. Автор үз исеменнән, шигъри чаралар белән, кешелек өчен мөһим булган билгеле бер гомуми хакыйкатьне сурәтләп бирә, бу нигездә берлек-күплек мәсьәләсе бергә керешә дип

әйтергә мөмкин. Әлеге мәсьәләне әдәбиятчы М. Гайнетдинов болай аңлата: «...лирик образ мәйданга китерелә һәм үзәккә куела. Заманны аңлау, аңа бәя, мөнәсәбәт, шул лирик образ халәте аша гәүдәләндерелә. Сәнгатьтә бу – әсәрнең үткенлеген, гомумиләштерү мөмкинлекләрен, сыгылмалылыгын арттыра, иң гади укучының да ул эмоциональ-интеллектуаль мөмкинлекләрен үз дәрәҗәсенә якынайта ала» [Гайнетдин, 2002, б. 10]. Шушы ук мәгънәне белдерү өчен, Ш. Зәки *-асы* кушымчалы теләк фигыльләрен дә файдалана: Игре йулларны куйубән туґры йулә варасы, / Тәрк идеб әґйары Тәңрейә йалварасы... [Татар поэзиясе..., 1992, б. 319]. Сүз сөрешеннән аңлашылганча, *-асы* формасы, хәзерге әдәби телдәге [Татар грамматикасы, 2002, б. 156] *-асы иде* аналитик теләк фигыль белдерә торган мәгънәгә туры килә.

Шагыйрь, шулай ук, аерым шигырьләрендә *-гым кели* аналитик формалы теләк фигыльне файдалана. «Назме дигәр Гафләт уйкусындан уйганым килер» дип башлана торган шигырьдә *-гым килер* дип тәмамлана торган фигыльләр, юл арадаш сигез тапкыр кабатланып, лирик геройның вафасызлык-гамьсезлек-икейөзлекне ташлап, лексик чаралар белән дә көчәйтелеп, көчле шәхес булырга кирәклеккә омтылышы-теләге тасвир ителә. Шул ук шигырьдән соңгы өзектә, *-гым* кушымчасы *бул* тамырына гына кушылып, *булгым килер* дип, юл аша дүрт тапкыр кабатланып, ныклы ният-теләк сурәтләнә: Кем ки Хакның дошманыдыр, бән аның дошманымән, / Кем ки Хакны сәүде – аңа ашнә булґым килер. / Әһле ґыйльме wә хилемә Хакдан чуқ кәрамәт вардыр, / Ул сәбәбдән бәндәи әһле сафа булґым кели. / Мәґкаде кәзбе, хыйәнәтдән һәмма бизар улыб, (Ялганчылыктан, хыянәтдән аптырап-йөдәп) Мәґкад сыйдық, сафада, бәстә па булґым кели (Тугърылыкка, сафлыкка нык бәйләнгән буласым килә)... [Гайнетдинов, 2002, б. 49–50].

Шулай итеп, Ш. Зәкинең поэтик әсәрләрендә *-айым, -ыйм, -ем, -а, -асы, -алем, -гай, -кәй* кушымчалы синтетик теләк фигыльләре һәм *-гым кели* формадагы аналитик теләк фигыльләре файдаланыла [Юсупов, 2006, с. 101–104].

Г. Кандалый, билгеле булганча, тирә-юнендәге кешеләргә, гаиләсенә, табигать күренешләренә турыдан-туры мөнәсәбәт белдереп, бигрәк тә, Сахибҗамал чибәр абыстайга бетмәс-төкәнмәс мәхәббәтен белдергәндә, үз исеменнән мөрәҗәгать итә. Шуңа күрә бу авторда үтенү-теләк мәгънәсенең барлык төрдәге кушымчалары эшкә җигелә, әмма сан ягыннан *-айым/-әйем, -ыйм/-ем/-ам, -а, -айын/-әйен,*

*-алым/ -әлем* күрсәткечләре белән белдерелә торган I зат берлек һәм *-айык/ -әйек, -ыйк/-ик* кушымчалы күплек сандагы теләк фигыльләренең актив кулланылуы күзәтелә, аларның мәгънә төсмере контекстта билгеләнә: Бу илләрдә торып қалсам, / Йарамас қызға күз салсам, / Атамның қарғышын алсам... / Қачыйм тизрәк бу илләрдин [Кандалый, 1988, б. 75]. *Качыйм* дигән теләк фигыль шарт фигыльләрдән аңлашыла торган шартлы гөман итүнең реаль тормышка ашуыннан шикләнүборчылу модальлеген белдерә. *-ем* һәм *-ыйм* кушымчалы фигыльләр чиратлаша: ...Бәнем дик сағышың күпме? / Дәйүб сорам ки анлардин. ...Ботақларың кемнәр кисде?! / Дәйүб срамки анлардин... [Кандалый, 1988, б. 89]; ...Бу қадәр моңлы зар берлән, / Бу қадәр иғтизар берлән, / Бу қадәр интизар берлән / Сорыйм сези, әйа балам [Кандалый, 1988, б. 91]. Аңлашылганча, игътизар, интизар белән көчәйтелгән үтенү, ялварулы теләкне белдерә. Шушы ук юнәлештә *-айым* формалы теләк фигыль файдаланыла: Тағын азрақ бән йазайым, йитәрме, / Бу хәсрәтләр йөрәкемдән китәрме [Кандалый, 1988, б. 93]. Шул ук кушымча белән II зат теләгенең тормышка ашырга тиешлеге белдерелә: Ишет, тыңыла, қыз, ишет, / Ки бер үгетемне биш ит, / Киңәшдән чықмый бер эш ит, / Күр улмайым дисәң, аппақ [Кандалый, 1988, б. 142].

*-ыйм* формасы белән сөйгән ярга эндәшеп, аның белән киңәшеп аңларга тырышуны, шөбһәләнүле теләкне белдерә: Йазыйм микән, йитәр микән, / Сәнең мәдхең бетәр микән [Кандалый, 1988, б. 139]; Ничек табыйм ла көй генәм, / Сөйләп бир, җанеки генәм [Кандалый, 1988, б. 141]. Рифмага туры китерелеп, теләкне белдерә торган кушымча кыскарып та кулланыла: Сәламләр әйләдем, җаным-гүзәлем, / Сәне күрмәй нә халь итеп түзәрем [Кандалый, 1988, б. 223]. Автор сөйгән ярына әйтәсе килгән теләген аңа эндәшеп, хикәяләү рәвешендә җиткереләчәген белдерә: Ки бән алдым қаләмемне, / Йазайым дип сәламемне [Кандалый, 1988, б. 107]; Қолақ салып ишет, җаным, / Идәйем бер хикәйәти [Кандалый, 1988, б. 158]. Шигырьләрендәге кебек үк, чибәр кызларга багышланган поэмаларында да автор аларга эндәшеп, көчле мәхәббәтен кабул итүләрен өметләнеп, инәлүле теләген үз исеменнән хикәяләү рәвешендә белдерүен дәвам итә: Сәңа ғашыйқ улып, Шәфғый, / Идәйем бер хикәйәти [Кандалый, 1988, б. 343]; Сүзем йазылды күп төрле, / Тагын да әйтәйем берне [Кандалый, 1988, б. 345] һ.б.

Бу поэмада, сүз җаена туры китерелеп, иярчен шарт җөмләнең баш җөмләсе итеп бирелә торган җөмләләрдә теләк мәгънәсе *-ам/-әм*

кушымчалы фигыльләр белән дә күрсәтелә: Нәчә мәдх әйләмәс бетмәс, Ғақыл дәхи фәһем итмәс, / Кәғазьдә һәм қара йитмәс, / Йазарға сурәтең, Шәфғый ...дип, тезелеп бирелә торган иярчен җөмләләрнең баш җөмләләрендә, чибәр абыстайның ефәк чәчләре, энҗе кебек тешләре, нәзек биле, талдай буе, шикәр-балдай теле сурәтләнеп бирелә: Йефәк сачле башыңныму, / Йаңа айдиқ қашыңныму / Һәм унбишдә йәшеңнемү, / Нә мәдх илә идәм рәфғый [Кандалый, 1988, б. 349] һ.б. Аңлашылганча, *кайсын хәлиткеч дәва итим, кайсын языйм, кайсын диим* дип гаҗизләнүле теләк белдерелә, теләк фигыль *-а/-ә/-и* кушымчалары белән бирелә. Әлеге кушымчалы фигыль белән теләк мәгънәсенең белдерелүе башка строфаларда да дәвам итәлә: Төсең-буйыңны, и җаный, / Қайу берин йазам, җаный... / Дил алырдай қочақларың, / Қайу берсен йазам, җаный... [Кандалый, 1988, б. 355] һ.б.

«Фәрхи» поэмасында абызтутыйга җиткерелергә тиешле хис-кичерешләр авторның «саба йиле» белән фикер алышуы алымында бара. Бу әсәрдә әлегә кадәр: Бән сезләрә бер сүземне, Йад итәлем, ки аңлағыл... [Кандалый, 1988, б. 173] дип, бер-ике мәртәбә генә файдаланган *-әлем* кушымчалы теләк фигыльгә мөрәҗәгать ителә: Назигем лә, үзәгем лә, гүзәлем, / Фәрхи, айғыл, ничек итеп түзәлем?! [Кандалый, 1988, б. 356] һ.б... Персонажның сүзләре итеп бирелә торган юлда *-асы иде* формасы белән көчле теләк белдерелә: «Кийәүгә барасы иде!» – Дәйүб үткәрде әүқадән... [Кандалый, 1988, б. 363]. *-ыйм* кушымчалы теләк фигыль II затка мөнәсәбәтле итеп бирелсә дә, гомуми затка каратылганы аңлашыла: Ағач башындағы қошны / Минеке дип әйтеп булмас, / Очып китсә йапан җирдән – Тотыйм дисәң, тотып булмас [Кандалый, 1988, б. 364].

«Мәгъшукнамә» поэмасында гашыйк булган кешенең хәлләре, тәгаенләнгән аерым шәхескә түгел, бәлки гомум укучыга каратыла, авторның III заттан бара торган хикәяләве I зат белән чиратлаша, бу уңайдан укучыга эндәшеп, аңа җиткерелергә тиеш зарлы-моңлы теләген хикәяләү рәвешендә белдерүе дәвам итәлә: Әйа ғариф, ачып қара күзеңне, / Бән әйтәйем, ки тыңлағыл сүземне [Кандалый, 1988, б. 373]; ...Әйа ғариф, йазайым бер хикәйәт, / Хәлаикъ қыйлмасын безне шикяйәт. Теләк төшенчәсе үзенең лексик атамасы белән дә кулланыла: Ләбем кибде теләк теләб Иляһым, / Грифтар булғаным – күпдер гөнаһым [Кандалый, 1988, б. 372]. I зат берлек сандагы теләк мәгънәсе *-алем* кушымчасы белән белдерелә: Сабырлық берлән әйтәлем сүземдин, / Бу ғыйшықлық бәнем үтде үземдин [Кандалый, 1988, б. 372]. *-айым*

кушымчасы белән чиратлашып бирелә: Җанашым, әйтәйем аңла! / Моны фәһем итсәнә, җаный [Кандалый, 1988, б. 380] һ.б. Түбәндәге юлларда *-гәй* кушымчалы фигыль кулланыла: Ки кяшки дөньйаға килмәгәй идең, / Бу ғыйшық җәфасын күрмәгәй идем [Кандалый, 1988, б. 385]. Сүз җаеннан, ягъни *идең, идем* ярдәмлекләреннән аңлашылганча, беренче җөмләдә II затка караган реаль булмаган шарт белдерелә: *дөньяга килмәсәң иде;* икенче җөмләдә I затка караган юклыктагы хәзерге-киләчәк замандагы *гыйшык җәфасын күрмәс идем* дип, үкенү белдерелә.

«Сахибҗәмал» поэмасында *-гай* кушымчалы фигыль, *-са* күрсәткечле реаль шартны белдерә торган иярчен җөмләнең баш җөмләсендә, II затка мөнәсәбәтле каратылган хәзерге-киләчәк хикәя фигыльнең мәгънәсе белән кулланыла: Мажик ир булса йулдашың, / Күңелдин китмәгәй йәшең [Кандалый, 1988, б. 392]; «Саба йиле»нә эндәшеп үтенү белдерелгәндә, *-са* күрсәткечле реаль шартны белдерә торган иярчен җөмләнең баш җөмләсендәге *-гәй* күрсәткечле фигыль, II затка мөрәҗәгать ителеп, өмет итүле теләк-үтенү мәгънәсе белән кулланыла: Сәба йиле, исәр булсаң, / Парау атлығ җайға, / Сәламемне тикергәйсән / Сахибҗәмал абыстайға... [Кандалый, 1988, б. 401]. Шундый ук төзелештәге җөмләдә *-гай* күрсәткечле фигыль II затка каратылган хәзерге-киләчәк хикәя фигыльнең мәгънәсе белән кулланыла: Өзелеп калса бер ғалим, / Йар итсәң бер надан залим, / Иманың қалмағай салим, / Ишет, бик бел, абыстай ла... Түбәндәге җөмләләрдә *-гай* күрсәткечле фигыль II һәм III затларга каратылган хәзерге-киләчәк хикәя фигыльнең мәгънәсендә файдаланыла: Надан ирнең күзе төтен, Дине һәм булмагай бөтен... [Кандалый, 1988, б. 405]; ...Қатып-қалҗып йөрер үзе, Чүгеп бөгелмәгәй тезе... [Кандалый, 1988, б. 407].

Авторның әлеге поэмасына кадәр үк, аерым шигырьләрендә *-гәй* кушымчалы фигыльләренең төрле затка каратылып кулланылуы күренә иде: Ки кяшки дөньйаға килмәгәй идем, / Бу хәсрәтләрне бән күрмәгәй идем [Кандалый, 1988, б. 77] дип башланган шигырендә беренче юлдагы *-гәй* кушымчалы фигыльнең I затка караган реаль булмаган шарт фигыль мәгънәсендә файдаланылуы аңлашыла: Бу хатымны йибәрдем бән пичәтләп, / Уқығайсән, җаный, боны хисаблап [Кандалый, 1988, б. 130] һәм шул ук типтагы: Моны йаздым сезгә, җаный, кисәкләп, / Уқығайсән, җаный, моны исәпләп [Кандалый, 1988, б. 241], дигән юлда *-гай сән* II затка каратылып, киләчәк заманга юнәлдерелгән мәгънәне аңлата.

«Сахибҗәмал» поэмасында башка әсәрләрендә сирәк кенә күренеп китә торган *-гай* формалы фигыльләрне еш кабатлый, нәтиҗәдә, аерым бер кызга белдерелә торган теләк гомумиләштерелеп кабул ителә, шәхси мәхәббәт кенә түгел, гыйлемлелеккә каршы куелган наданлык, наданлыкның үтә чыккан ярамаганлыгына ышандырырга теләү тасвир ителә. Сурәтләү лексик чаралар белән көчәйтелә. *-гай* кушымчалы фигыльләрнең әлеге мәгънәсе белән авторның «Бән сезләрә бер сүземне, / Йад идәлем, ки аңлағыл / Қолақ дотып бу сүземне, Ихлас берлә ки дыңлағыл» дип, башлана торган шигырендә дә надан кешегә карасаң, Аллаһы да разый итмәс дип, наданлыкның ни дәрәҗәдә начар булуы сурәтләнгәндә тезелеп файдалануы күренгән иде: Наданның хале бу улғай, / Чабатасына туфрақ тулғай, / Ойықы һәм қара булғай, / Чықуб хатун кағар аный [Кандалый, 1988, б. 175–176]. Инде автор үзенең «...кешеләрне изге нияткә, яхшы гамәлгә, димәк, чын мөселманлыкка чакырган «нәсаих»тан, ягъни үгет-нәсихәтләрдән гыйбарәт [Кандалый, 1988, б. 18] «Рисаләи-л-иршад» («Тугъры юлга күндерүче китап») исемле дини-дидактик «вәгазьләр бабедин» булган беренче поэмасында да шул ук *-гәй* кушымчалы фигыльләрне бер-бер артлы тезеп файдалана: Йегетлек йил кеби үткәй, / Қарилық фи-з-зәман йиткәй, / Бақып күр халеңи: ниткәй, / Фәсадәтдә үтеп рузгяр [Кандалый, 1988, б. 252]. Сүз сөрешеннән, *-кәй* күрсәткечле фигыльләрнең III затка каратылып, яшьлек җил кебек үтә (үтәр), картлык тиз заман җитә (җитәр), халең ничек була (булыр) дип әйтергә мөмкин булуы, хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең мәгънәсендә кулланылуы аңлашыла. Бозыклардан, мәкерлек эшләүчеләрдән, хыянәтче, икейөзле, үҗәт, ахмаклардан ерак торырга кирәклек фикере түбәндәге юлларда бирелә: Шәйатин, бел, ғөдур улғай, / Хакында гөфтегү қыйлғай / әр җөстеҗү қыйлғай, / Заляләтдә бә-иҗтиһад, ягъни бел, шәйтаннар оятсыз булла (булыр), чынлыкта әңгәмә кыла (кылыр), мәкерләр казыну кыла (кылыр), бозыклыкта тырышлык белән. Димәк, хәзерге-киләчәк заманны белдерә торган хикәя фигыль мәгънәсендә файдаланыла торган *-гай* күрсәткечле фигыльләрне автор гомум мәгълүм хакыйкатьне дини-дидактик һәм көнкүреш-тормышчан нигездә үгетләү, нәсыйхәт бирү өчен уңайлы чара буларак, эзлекле рәвештә тезелеп бара торган боеру мәгънәсен белдерә торган фигыльләр белән бергә яратып файдалана.

Шуның белән бергә, «Ки бән алдым қаләмемне, / Йазайым дип кәлямемне, / Йаза белмим кәлямемне, – Кем илткәй бу сәламемне?»

[Кандалый, 1988, б. 107] дип башлана торган шигыренең һәр дүртьюллыгы ахырында алты мәртәбә кабатланып бирелә торган хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең мәгънәсендәге *-кәй* кушымчалы фигыльнең бер үк вакыта өмет итү һәм шикләнүен белдереп кулланылу да мәгълүм. Шулай итеп, Г. Кандалый иҗатына нигезләнеп, *-гай* һәм *-ай (ым, ык)* формалы теләк фигыльләренең охшашлыгы истә тотылган хәлдә, *-гай* формасының функциясе ягыннан үзенчәлекле булуын танырга туры килә [Щербак, 1976, с. 184–186].

«Сахибҗәмал» поэмасында да җаныкайга турыдан-туры эндәшеп, инәлүне теләк *-ыйм* кушымчасы белән белдерелә: Ничек табыйм ла көй генәм? / өйләп бир, җанеки генәм! / Матурым, җанеки генәм, Йазып йибәр дәхи хатлар [Кандалый, 1988, б. 416]; ...Кемне генә табыйм икән, Күреп Сахибҗәмалымны, / Ғыйшыкымны бәйан итеп, Сөйләп бирердәй халемне [Кандалый, 1988, б. 422]. Димәк, шәхси теләк белдерелгәндә, авторның барлык әсәрләрендә дә, тыңлаучыга эндәшеп төрле төсмерле теләкне белдерү өчен *-айым, -ыйм, -ем* кушымчалы фигыльләр ясатып кулланылуы күренә.

Теләк фигыльнең I зат күплек саны *-айык/-әйек* кушымчасы белән белдерелә: Болай торганча икәү ары-бире, / Қушылайык икәүләп, китмә кире [Кандалый, 1988, б. 151]; ...Әгәр чәнди мәне мәхрүм итәрсәң, / Күрәйек нинди йегеткә китәрсән [Кандалый, 1988, б. 161] һ.б.

Шулай итеп, Г. Кандалыйның шигырь һәм поэмаларында, авторның үз исеменнән чибәр абыстайларга мәхәббәт белдерелгәндә, *-айым/-әйем, -ыйм/-ем/-ам, -а, -айын/-әйен, -алым/-әлем* күрсәткечләре белән белдерелә торган I зат берлек һәм *-айык/-әйек, -ыйк/-ик* кушымчалы күплек сандагы теләк фигыльләренең ясатып кулланылуы күзәтелә, аларның өмет итү, үтенү, борчылу, шәфкатьлерәк булырга кирәклек, мөмкинлек кебек төсмерләре контексттан, ягъни башка сүзләр белән бәйләнешеннән аңлашыла.

Аерым формалар, төрле шигырьләрдә дә билгеле бер сүзләр белән кабатланып файдаланыла. Мәсәлән, шактый сирәк күренә торган *-алем* кушымчасы: Бән сезләрә бер сүземне, Йад итәлем, ки аңлағыл... [Кандалый, 1988, б. 173]; Фәрхи, айғыл, ничек итеп түзәлем?! [Кандалый, 1988, б. 356].

*-гай/-гәй, -кай/-кәй* күрсәткечле фигыль, асылда, иярчен шарт җөмләнең баш җөмләсе итеп бирелә торган җөмләләрдә реаль булган, яисә реаль булмаган шартларга бәйле булачак хәзерге-киләчәк заман мәгънәсендә, гомум мәгълүм дини-дидактик һәм гыйлемлекне мактап,

наданлыкны хурлап язылa торган өзекләрдә кулланыла. Димәк, Г. Кандалый иҗатында традицион рәвештә теләк фигыль кушымчасы дип санала торган күрсәткечнең функциясе башкачарак вазифа үти була.

Теләк мәгънәсе аналитик формалар белән дә белдерелә: Йазыйм микән, җитәр микән / Йазу файда итәр микән / Бу кайғулар бетәр микән / Ғомерлеккә китәр микән?! [Кандалый, 1988, б. 73]; *Языйммы икән*, *җитәрме икән* дигән тезмәләрдә шикләнүле, борчылулы теләк белдерелә. Персонажның сүзләре итеп бирелә торган юлда *-асы иде* формасы белән көчле теләк белдерелә: «Кияүгә барасы иде!» – Дәйүб үткәрде әүқадән... [Кандалый, 1988, б. 363].

III зат берлек сандагы *-сен* боерык фигыле *имди* ярдәмлеге белән Ходайга ялварулы, өмет итүле көчле теләкне белдерә: Сәнең өчен эреп сарқа йөрәк майым, / Фазле берлән сәне бәңа бирсен имди... / Кичә-көндез телләремдә сәндер сүзем, / Бер Ходаем сәни бәңа бирсен имди... [Кандалый, 1988, б. 109] һ.б.

*-са иде* формасы белән каргаулы теләк белдерелә: Барған ирең торсайде чыбырқы тағып, / Көне-төне торса иде алып-чағып, / Суқған йирең чықса иде қара йанып, / Шул wақытда бән исеңә төшәрем имди… [Кандалый, 1988, б. 114]. Шул ук форма белән үтенүле теләк белдерелә: Хода нөсърәт бу көн вирсәйе безгә, / Қаләм тотып сәлам йазсайы сезгә... / Ходайым йазса иде, күрсәм иде, / Сәнең гөлтик йөзеңдин үпсәм иде [Кандалый, 1988, б. 385-386] һ.б.

*-са + на, -са + чы* формасы белән үтенүле теләк белдерелә: Сағынып, и Фатыйма ла, / Килсәнә бер қатыйма ла... [Кандалый, 1988, б. 133]; ...Бисмилла дип ки башладым ки кәлямем, / Хуш улсачы бәнем йазған сәламем... [Кандалый, 1988, б. 384] һ.б.

*-у кәрәк, -ырга кирәк имди* формасы теләк белдерү мәгънәсе белән кулланыла: Сән дә бәне йаманласаң, үзең йатлап / Бу дөньйаны ташлап китү кирәк имди ...Күрмәймүсән: сары тулды нурлы йөзгә? / Бу сүзләргә ышанырға кирәк имди [Кандалый, 1988, б. 111] һ.б.

Шулай итеп, Г. Кандалыйның шигырь һәм поэмаларында, авторның үз исеменнән чибәр абыстайларга мәхәббәт белдерелгәндә, *-айым/-әйем, -ыйм/-ем/-ам, -а, -айын/-әйен, -алым/-әлем* күрсәткечләре белән белдерелә торган I зат берлек һәм *-айык/-әйек, -ыйк/-ик* кушымчалы күплек сандагы теләк фигыльләренең бик тә актив кулланылуы, тагын *-са + на, -са + чы* формаларының булуы күзәтелә, аларның өмет итү, үтенү, борчылу, шәфкатьлерәк булырга кирәклек, мөмкинлек кебек төсмерләре контексттан, ягъни башка сүзләр белән

бәйләнешеннән аңлашыла, *-гай, -гәй ,-кай, -кәй* кушымчалары, асылда, хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең мәгънәсендә аңлашыла, һәм шулай ук *-ыйммы икән, -әрме икән, -са иде (сайде), -ү кәрәк, -ырга кирәк* аналитик кушымчалар белән дә, төрле төсмерләре белән катлауландырылган теләк мәгънәсе белдерелә [Бәширова, 2015, б. 96–114].

XIX гасырның икенче яртысы – XX йөз башында язылган Ә. Уразаев-Кормаши кыйссаларының тезмә өлешендә *-айын, -әйен* күрсәткечле теләк фигыль файдаланыла. «Кыйссаи Бүз йегет»тә (1874): Әй җан дустым, йақын кәл, сүзем сиңа әйтәйен, / Әҗәл кәлде бу башқа, алла әмерен қайтайын, / Сәндин башқа дустым йуқ, серем кемгә әйтәйен [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 30]; ...Сездин дөньйа үтебди, мән дә артындин китәйен, / Сән алдымда йөрмәсән, бу дөньйаны нитәйен [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 40] һ.б.

«Кыйссаи Таһир илә Зөһрә»дә (1879) *-айын* кушымчалы теләк фигыль шигъри-тезмә һәм чәчмә өлешләрендә бер үк мәгънәдә кулланыла: Күңеленнән әйтде кем, бу дәрwиш бикяр кеше түгелдер, моның қулын үбәйен дип, дәрwишнең қулларын үбте [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 4]; Бу мәлғун ғарәп... ғарыз қыйлды: Тәқсыйр ханым, сезләргә, мин бер сүзем әйтәйен, / Бер серемне сезләрдән айап сақлап қайтайын [Уразаев-Кормаши, 1894, б. 13].

Әлеге өзекләрдә *-айын* формалы теләк фигыльләр дә, *-айым* кушымчалы төрләре кебек үк, яки тыңлаучысына, яисә үз-үзенә билгеле бер эш эшләргә теләк булуын, бу теләкнең сөйләү моментында, я булмаса якын киләчәктә үтәлүен белдерәләр. Әлеге кушымчалы фигыльләр бер үк контекстта чиратлашып килергә дә мөмкин: Андыйн соң Таһир Зөһрәгә әйтде: И минем Зөһрәм, әгәр дә мин дөньйада сездән ғайре йар сөйсәм, уйыма җитмәйен, әгәр дә сез бездән бүтән йар сөйсәңез хақ тәбарәкә wә тәғаләдән теләймен ки, сез шул сәғатьтә һәлақ буласыз, – диде [Татар әдәбияты..., 1957, б. 292–293].

Авторның үз исеменнән әйтелеп бирелә торган I зат күплектәге киң *-айык* формалы теләк фигыльләр, тар язылыштагы *-ыйк* күрсәткечләре белән чиратлашып, асылда кыйссада бара торган вакыйгаларның берсен икенчесенә бәйләү вазифасын үти: Хасыйле қалям, сүзне қысқа қыйлыйқ, бераз кәйеф қорыйқ [Татар әдәбияты..., 1957, б. 295]; Хасыйле кәлям, сүзне қысқа қыйлайық, безләр кәйеф қорайық [Татар әдәбияты..., 1957, б. 306] һ.б.

*-айын* формалы теләк фигыль тагын Себер якларында туып-үскән М. Йомачиков шигырьләрендә дә күзәтелә: Мәсәлән, аның «Шаһсәнәм

һәм Гъәриб» поэмасында: Бу көн сәңа дәрд халене әйтәйен, / Буйының тотыб, мәхкәм қочыб йатайын, / Мә гөлниһал күңелемдәге дәрдне әйтәйен, / Кил, икемез ғишрәт қылыр җай икән... [Татар поэзиясе..., 1992, б. 357].

Теләк фигыльнең әлеге формасы башка шагыйрьләр иҗатында сизелерлек күзәтелми булса кирәк.

Теләк фигыльнең Орхон-Енисей язмаларыннан ук килә торган *-ал+зат* кушымчалы төре дә [Нуриева, 1978, б. 104], классик әдәби традициянең дәвам ителеше буларак, Ә. Уразаев-Кормашиның кыйссаларында да үзенең вазифасын башкарган хәлдә файдаланылуында була: Буны үлтерәле, тиделәр,... суғыш берлә үлтерәле, тиделәр [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 17]; ...хәйлә берлә үлтерәле диб.... [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 18] һ.б.

Шулай итеп, Ә. Уразаев-Кормаши кыйссаларында *-ал* кушымчалы теләк фигыльнең *-але, -алем, -алек* формалары кулланылганы күзәтелә. *-алем* формасы Г. Чокрый иҗатында күренеп киткән иде: Булса ғәйбең, ғәйрегә қылма мәлам, / Булмаса, без күрәлем синдән кәлам... [Татар поэзиясе..., 1992, б. 337].

М. Акмулла иҗатында боерык фигыльнең III зат *-сын* формасы белән II яисә гомуми затка каратылган теләк мәгънәсе белдерелә: ...Ходайым инсаф бирсен күңлеңезгә, ...Аһ дәриға, эч тазарсын, эч тазарсын / Булмаса – файда бирмәс қоры белем [Акмулла, 2001, б. 36] һ.б. Шул ук форма белән авторның ирониясенә төренгән теләге белдерелә: ...Йәшемез үткән сайын күңлемез йәшь / Тәүбәне соңырырақ қылачақмыз / Ғаwамға бер ақ сәлләң өлкән булсын / Атың-чанаң, кийемең күркәм булсын / Хосусән җаһил халық нәзарендә / Үзең – симез, қорсағың өлкән булсын [Акмулла, 2001, б. 51] һ.б.

Г. Тукайның аристократ-абруйлы иске татар телендә язылган (хәзерге телгә тәрҗемә ителә торган) шигырьләрендә теләк фигыль ерак гасырлардан традиция булып килүче күрсәткечләләре белән кулланыла. *-алем/-әлем* формалы теләк фигыль: ...Ғолүмең бақчасында дулашалем, идәлем сәйран, / ...Борынғы уйқуларны дөшенүбән улалым надим, / Тәрәққый wә тәғали йулларына улалем қадим... [Тукай, 1985, б. 24]; И қаләм! Китсен әләм, син әйлә безне шадыман, / Без дә сайандә улалем туғры йула қадиман (Китсен газап, ит син безне шат / Без дә синең арканда туры юлга басыйк аяк) [Тукай, 1985, б. 56] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, *-алем/-әлем* кушымчалы теләк наклонениесенең күплектә кулланылуы күренә. Әлеге шигырьләрдә теләк фигыль-

нең традицион формасы гадәти тел берәмлеге булып файдаланыла. Ә менә «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» поэмасында *-алем* формасы образ барлыкка китерү чарасы буларак махсус сайлана: Алдыбызда ат кәмитен күрәлем / Һәм Микитин җәмғатенә ирәлем [Тукай, 1985, б. 260]. Түбәндәге юлларда *-алем* формасы, асылда, рифмадаш сүз буларак кирәк була: Қар, томаннан көтмәгәндә килде чықты Шүрәлем / Дәшмимен. Тып-тын торам. Нишләр икән, дим, күрәлем [Тукай, 1985, т. 2, б. 231]. Бу вазифада *-алем* кушымчасының берлек сандагы мәгънәсе белән кулланылуы аңлашыла.

*-айым/-әйем/-ыйым/-ийем* кушымчалы теләк фигыль, шәхси хис кичерешләрне тасвирлау чарасы буларак, берлек санда «Гыйшык бу йә!...» шигыренең төп сурәтләү чарасы булып файдаланыла: ...Бер гидайы җан фидайым, ғыйшқыңа пәрwанайым, / Кәл, гүзәл, ғарз ит җәмалың, йанайым, кәл йанайым. / И ходайым, вир ғақыл, чөн хәбсә мәхбүс улмыйым, / Бу қызың ғыйшқында бән диwанайым, диwанайым... [Тукай, 1985, б. 68]. «Дәрдеменд дәгелмием» шигыре дә *-айым/-әйем* кушымчалы теләк фигыльнең кабатлануы белән язылa [Тукай, 1985, б. 82] һ.б. Аерым бер шигырьдә кабатланып килә торган теләк формасы ритм-рифма-көен хасил итә.

Г. Тукайның, традицион формалы теләк фигыльләре белән бергә, шул ук шигырьләрендә, хәзерге әдәби телдә норма булып санала торган *-ыйм/-им, -ыйк/-ик* күрсәткечле фигыльләрнең дә файдаланылуы, алга таба әлеге форманың, шигырьләрдә әйтелә торган фикерне укучыга җиткерүдә төп тасвир чарасы буларак, эзлекле рәвештә кулланылуы күзәтелә: ...Файдаланыйқ киңлектән, wаз кичик мин-минлектән, / Көчле-көчсез тиңлектән файда алыйқ, бәдәwам. Җыйналып мәҗлес йасыйқ, Бер-беребездән қачмыйқ, / Наданлыққа йул ачмыйқ, – Бик күп изде, бәдәwам... [Тукай, 1955, б. 10] һ.б. Г. Тукай шигырьләрендә тагын, сирәк кенә булса да, *-сачы,-са икән, -са иде* формалары да теләк мәгънәсен алып килә: Аһ, булсачы wәзирләрем, тәхтем минем... / ...Кирәк түгел, ди, хан булу һәм баш булу, / Насыйп булса икән миңа қойаш булу... [Тукай, 1955, б. 58].

Г. Тукайның балалар өчен язган шигырьләрендә *-асы килә* формалы теләк фигыль файдаланыла: Йуқ, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә / Шул болыннарда йатасым, шунда ауныйсым килә (Кызыклы шәкерт). ...Тел очында бар бугай бер бик кызык, үткен сүзе,/ Ни сәбәптәндер яшергән, әйтәсе килми үзе.... / Бик ашыйсы килсә дә

барса да ачтан үлеп, / Сузыла ул ашка, ашыкмый, бик суфыйланган булып (Мияубикә) һ.б.

Г. Тукай иҗатында татар телендә каргауны белдерә торган *-гыры* формалы теләк фигыльләрнең файдаланылуы билгеле. «Матбага берлән уйнаган бер байга» шигырендә: И айағың корғыры! Намусыбызны, таптадың, / Зольмәтеңнең хөрмәтенә шәмсебезне капладың [Тукай, 1955, т.1, б. 103]. «Су анасы»нда: Ни кирәк? Кем бу? Қара төндә wақытсыз кем йөри? / Нәрсә бар соң төнлә берлән, и пычағым кергере [Тукай, 1955, т.1, б. 192]. «Бичары куян» шигырендә: Йәшь балаларны ашап китте бүре, / Бик усал йыртқычтыр ул, мул қырғыры [Тукай, 1955, т.1, б. 134].

Дәрдемәнд иҗатында теләк фигыльләр еш кабатлана дип әйтеп булмый. Менә берничә вариантта язылган бишек җыры «Бәллү»дә киң язылышта теләк фигыль күзәтелә: Қыйғач қашым, / Асыл ташым / Йоқлайық икәү... / Алмақайым, Аппаққайым, / Йоқлайық икәү... / Кил, гөлкәйем, Сөнбелкәйем, / Йоқлайық икәү [Дәрдемәнд, 1980, б. 54].

Дәрдемәнд каләмдәшләре тарафыннан бөтенләй диярлек кулланылмаган, хәбәр вазифасын үти торган инфинитивны теләк мәгънәсе белән файдалана: йазып терсәк, басып қуллар бөйергә, / Қурай салмағына басып бийергә [Дәрдемәнд, 1980, б. 172]. Шагыйрьнең әлеге үзенчәлеге «Татар грамматикасы» хезмәтендә дә ассызыклана [Татар грамматикасы, 2002, б. 156].

Татар прозасында риваять сөйләүчеләрнең сүзе кабатланып сөйләнә торган кыйссаларда теләк фигыль яратып кулланыла. Эзлекле булып К. Насыйри иҗатында, бигрәк тә сәнгатьле проза әсәрләрендә яратып файдаланыла. «Кырык вәзир кыйссасы»нда: ...уғландан мин бер хәбәр алайым, күңлендәге қайғусин wә хафачалығын китерәйем, ...китер, күрәйем, ...килеңез, бер хикәйәт сөйләйем [Татар әдәбияты, 1957, б. 172] һ.б.

Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, К. Насыйриның әлеге кыйссасында *-айым, -әйем, -ыйм, -им* кушымчалы теләк фигыльләр эзлекле булып киң язылышта, шактый сирәк очракларда гына тар язылышта бирелә. (1974 елгы басмада киң язылыш, рәттән диярлек, тар язылышка әйләндерелгән.) Күп төрле мәгънә төсмерләре белән кулланыла: кирәк булган эшне эшләргә җыену, чын теләк белән эшләргә әзер икәнлекне аңлату, тыңлаучы риза булса гына эшләргә теләк белдерү һ.б. Күпчелек җөмләләрдә сөйләүченең теләген белдерә торган фигыль тыңлаучыга нәрсә дә булса эшләргә боеруны аңлаткан

фигыльләрдән соң килә, боерылган эш белән үтәлергә тиешле теләкне аңлата. «Кырык бакча» әсәрендә дә, нигездә, шундый тип җөмләләр дәвам итәлә: Ул карт: Туқта, мин сезнең сүзегезгә җаwап бирәйем, – дип ишәген туқтатты [Татар әдәбияты, 1957, б. 199]; Менә қулымда қамыр бар икән, алай булса, йуып бирәйем, – дип табаққа су салды [Татар әдәбияты, 1957, б. 200] һ.б.

«Фәвакиһелҗөләса»дә: Йә шәйех, қабул ит, бу чапанымны сиңа һибә қылайым, – диде [Татар әдәбияты, 1957, б. 213]; ...Йуқ алайса, син һәнүз фәқыйрь икәнсең, чапаныңны қабул итмәймен, – диде [Татар әдәбияты, 1957, б. 213] һ.б. Шул ук беренче зат берлек сан киң язылыштагы теләк фигыльләре кулланыла.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда теләк фигыльләре шул ук тәртиптә бара: Аулақта ниқәдәр һөнәр эстәсәңез, баш өсте, күрсәтик, – диде... Ни хезмәтеңез бар, бойырыңыз, йибәрим, хәзер китерсен, – диде [Насыйри, 1974, б. 217]; Рәхим итәсез, ике-өч көнлек ғомерне бергә кичерәйек, мөмкин қадәр бер-беремезгә хезмәт күрсәтәйек, вәссәлам, – дип намәсен тәмам қыйлып, [Насыйри, 1974, б. 222].

Мисаллардан аңлашылганча, К. Насыйриның сәнгатьле әсәрләрендә теләк фигыль, гадәттә, сөйләүченең тыңлаучыга нәрсәне дә булса эшләргә кушкан, боерган, үтенгән фигыльләрдән соң килеп, шул боерык үтелгәннән соң гына, яисә аның белән берлектә тормышка ашачак эш-хәлләрне үтәргә әзер булуны аңлата, тулы кушымчасы белән кулланыла. «Әбүгалисина кыйссасы»нда, авторның укучысына мөрәҗәгать иткәндәй, вакыйгаларның барышын җитәкли торган җөмләләрдә, теләк фигыль күплек санда файдаланыла: Бу арада Әбелхарис қыйссасы тәмам булып, без киләйек мақсуд асылы булган Әбүгалисина қыйссасына [Насыйри, 1974, б. 225]; ...хәлвәфрүш белән қыз ғыйш-ғыйшрәттә булсынлар, без киләйек илче хикәйәтенә [Насыйри, 1974, б. 248]. Бу төрдәге җөмләләрдә теләк фигыль боерык фигыль белән бәйләнмәгән позициядә дә кулланыла һәм мондый җөмләләр әсәрне хикәяләгәндә дә күзәтелә: ...һаман үзенең арзусына қарый торған бер адәм икән, дип, ачуланып китте һәм ишектән типкәләп чығарыйм дип берничә мәртәбә фикер қыйлды, йәнә сабыр итде [Насыйри, 1898, б. 19]; Әбүғалисинаны дүпәләп қыйнап чығарыйм дигәндә, Әбүғалисина айақ үзрә торып, хәлвәфрүшнең қулыңдан мәхкам тотып, ишеккә таба селекде [Насыйри, 1898, б. 20] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, бу төр җөмләләрдә теләк фигыль *дип*, *дигәндә* ярдәмлекләре белән бергә килә һәм кыек сөйләмне

формалаштыра. «Әбүгалисина»да *-алем* күрсәткечле теләк фигыль күзәтелә: Кил, ғыйш-ғыйшрәт қыйлалем, – диде [Насыйри, 1898, б. 28]. Бу әсәрдә *-асы килә* формалы аналитик формадагы теләк фигыль кулланыла: ...Минем һәм аның әхwәлене беләсем килә, – диде [Насыйри, 1974, б. 291] һ.б.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда (1887), К. Насыйриның кыйссаи текстларындагы кебек үк, I зат берлек һәм күплектә зат кушымчалары алган теләк фигыльләре киң вариантта языла, әмма тар язылыштагы вариант та файдаланыла: ...Сәғыйдә әйтде, ул хикәйәтне сөйлә, ишетеп белим, – диде [Фәизхан, 1896, б. 2]; Хикәйәт ничек, сөйлә, ишетәйем, диде [Фәизхан, 1889, б. 24, 25] һ.б.

Татар прозасының автор үз сүзен сөйләп хикәяләнә торган икенче төрен башлаган М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» (1886) романында да *-айым, -айык, -айук* формалы теләк фигыльләр кулланыла: Бу кяфер эшидәндер, бән аны күрәйем, хараб идәрмән [Акъегет, 1886, б. 14]; ...ки, бақайық [Акъегет, 1886, б. 27].

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә *-айым* кушымчалы фигыль тагын түбәндәге җөмләләрдә башка әдипләрдә очрамаган мәгънә төсмере алып килә: – Ниндәй әдәб? ...Бәңа фән китабларының файдасыны инкяр идәрләр дә, бән дә бөйлә кешеләрнең сүзләрене әдәб илә дыңлайым? Фаидәи исламийа өчен чалышмақымны диле wә буш эшдән сайурлар да, бән анлара әдәбле улайым? Бөйлә ғақыллы ишәкләр фән белмәкемне зарар сайурлар да, бән анларый хурламайым? Бөйлә мөселманларый хурламақ аздыр, йөзләренә төкереб, анлардан чәверелмәк кәрәк... [Акъегет, 1886, б. 62, 82]. Аңлашылганча, әлеге өзектәге *-айым* кушымчалы теләк фигыльнең барлыгы, аның юклык мәгънәсендә булырга тиешлекне белдерә.

*-алем* кушымчалы теләк фигыль М. Акъегетнең әлеге әсәрендә, нигездә, авторның укучысына эндәшеп, әсәрдә бара торган вакыйгаларны җитәкләү чарасы булып файдаланыла: Әмма без Хисаметдин менла артындан кидәлем [Акъегет, 1886, б. 8]; Хәзердә сүз ачылдықда хәбес итмәк хақында берәр сүз дийәлем [Акъегет, 1886, б. 30, 63].

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә дә (1887) *-алем* күрсәткечле теләк фигыль, «Хисаметдин менла» романындагы кебек үк, автор тарафыннан вакыйга барышын, персонажлар белән таныштыру өчен уңайлы бер чара булып кулланыла: Тәфтишчеләр әхуәлене йазалем [Бигиев, 1991, б. 222]; Шимди нумирәсене тәғриф

идәлем [Бигиев, 1991, б. 222]. Әмма әлеге әдиптә шул ук вазифаны тагын *-айым* кушымчалы фигыль дә башкара: Ғабденнасыр әфәнденең кем идекене белдерәйем [Бигиев, 1991, б. 226]. Бу әсәрдә, гомумән, *-алем, -айым* кушымчалы теләк фигыльләре бер үк вазифаны, берсе икенчесе белән алмаштырылып, чиратлашып үтиләр: Сезләрә дә, хөрмәтлү уқучыларым, Мусаның ниндәләйен адәм идекене белдерәйем [Бигиев, 1991, б. 223]; Ғыйззәтлү уқучы, Ғабденнәсыр әфәнде җәнабе сәғадәтләреңезә дә мәғлүм түгел, Ғабденнәсыр әфәнденең кем идекене белдерәйем [Бигиев, 1991, б. 226]. *-алем, -айым, -ыйм* формалары персонажлар сөйләмендә дә параллель файдаланыла: ...Анлар бәңа, әйдә, сәне бундан без чықаралем, дип, икесе ике қулымдан тотып, бигрәк қараңғурақ йиргә илтеп қуйдылар [Бигиев, 1991, б. 227]; Мән шимди нә қыйлайым. ...Мән нә мәслихәт қыйлайым. ...Ниндәләйен эшдә йәрдәм қыйлайым? [Бигиев, 1991, б. 228].

Мисаллардан аңлашылганча, теләк фигыльләр, гадәттә, персонажларның рухи халәте, хис-кичерешләре белән бәйле хәлләрдә, нәрсә эшләргә белми аптыраган вакытларында ешрак кабатлана.

З. Бигиевның «Гөнаһе кәбаир» (1890) романында да теләк фигыльләр, нигездә, шундый ук вазифа үти, ягъни авторның үз сөйләмендә, укучысы белән бергә хәл ителергә, күрелергә тиешле эшне атый: Маһруйның бишекдә wә сабавәтдә улан халенә нәзар идмәйенчә, унсәкез йәшендән улан әхуаленә бақалем [Бигиев, 1991, б. 257]. Тик бу төрдәге мисаллар әлеге әсәрдә шактый аз, теләк фигыльләр персонажлар сөйләмендә активрак: Әгәр дә Қазанға кәлеп тәхсыйле ғолүм қыйлайым дисәң, туғры дамелла Ғабделғалләм хәзрәт мәдрәсәси кеби олуғ мәдрәсә йуқдыр [Бигиев, 1991, б. 258]; Абыстай, зинһар, шул баланы қулында тотып торсана, мин әнкәсене чағырайым... [Бигиев, 1991, б. 263] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, З. Бигиевнең романнарында, персонажларның сөйләмендә, нигездә, I зат берлек сандагы, киң формадагы язылышта чагыла торган теләк фигыльләре файдаланыла, аларның күбесе шул үзара сөйләшүчеләрнең тормышларындагы четерекле хәлләрдә нәрсә эшләргә белмичә аптыраган халәтләрен тасвирлап бирү чарасы буларак бирелә.

Әдипнең «Мавәраэннәһәрдә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» (1908) авторның үз исеменнән язылганга, бу төр фигыльләр дә аерым шәхеснең теләген белдерә: Кидәйем, күрәйем, ул тарафда дин карендәшләремезең шимдеки хальләрени әүwәлге хальләренә қыйас

идеп, ғыйбрәт алайым дидем [Бигиев, 1908, б. 2–3]. Юлда очраган кешеләр белән сөйләшкән вакытта, аларның теләкләрен аңлата торган теләк фигыльләре *-айым* һәм *-алем* формаларында кулланыла: – Разый улырсаңыз, мосье, икемез бәрабәр чәй эчелем, – диде. ...бән сезләрә бер рисалә һәдийә қыйлайым [Бигиев, 1908, б. 16]. Күренгәнчә, әдипнең сәяхәтнамәсендә, аның әдәби әсәрләре белән чагыштырганда, теләк фигыльләр шактый санаулы гына файдаланыла.

Р. Фәхретдиннең сәнгатьле прозасында да әлеге фигыльләр шактый сирәк күзәтелә, булганнары да «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) әсәрендә вакыйгаларны бер-берсенә бәйли торган, турыдан-туры авторның үз мөнәсәбәтен белдерә торган юлларда чагылыш таба: ...һәр нә исә безләр бу бәхәстән кичәлем... [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 331]; ...бойырыңыз, боның хақында сезләргә бер-ике сүз сөйләйәлем. ...бойырыңыз, сезләр илә бәрабәр кереп күрәлем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 336].

Күренгәнчә, *-әлем* кушымчалы теләк фигыль М. Акъегет, З. Бигиев әсәрләрендә кулланылган тәртипне дәвам итә, ягъни әдипнең турыдан-туры укучысына эндәшеп, аның белән берлектә, аның теләген үтәү йөзеннән башкарылачак эш-хәлләрне аңлата.

Ф. Кәрими әсәрләрендә дә, теләк фигыльләренең кулланылышы, асылда, шушы тәртиптә бара, ягъни авторның үз исеменнән әйтелә торган теләге дә, персонажлар сөйләмендә бирелә торган теләк тә белдерелә. «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә (1897): Бөтен зиһенем wә фикерем илә шул қызның кем қызы икәнен ничек итеп қайдан өйрәнәйем дә тағын бер күреп сөйләшәйем, дийә хыйал итмәкдә идем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 227]; ...Кем қызлары икәнлекләрене бик беләсем килсә дә, мөмкин булмады [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 227]. «Җиһангир мәхдүмнең ауыл мәктәбендә укуы» (1900) хикәясендә: «Мондан артық тәқый ғаҗәб таңлары вар» дийәрәк шимди хәтме кәлам идәйем [Кәрими, 1996, 245]. «Шәкерт илә студент»та: Асыл бәхәскә киләлем... [Кәрими, 1996, б. 49]. «Нуретдин хәлфә»дә: ...Иң әүwәл һәркөн өстеңдә йәшәдекемез wә үлдекдән соңра эченә күмелеп йатдықымыз «йир»нең әхwәлен, яғни «ғыйльме җәғрәфийә» илә «ғыйльме табиғател әрз wәл мәғдән»не үгрәнәлем… [Кәрими, 1996, б. 69]. «Морза кызы Фатыйма» (1901) әсәрендә: ...ләкин ничек җәсарәт итеп тә аңдаен адәмнәргә чәчәк кундерәйем [Кәрими, 1996, б. 84]; ...шимди асыл мақсатқа киләлем дә сүземезе ачықтан-ачық сөйләлем [Кәрими, 1996, б. 97] һ.б.

Нигездә, *-алем* формасы ешрак кабатлана, авторның үз исеменнән күплек санда *(без)* сөйләве аңлашыла.

Кайбер башка мәгърифәтче әдипләрнең әсәрләрендә дә *-алем* формасы күзәтелә. Г. Гафуров-Чыгтайның «Тутам» (1906) рисаләсендә: Қайда хәмийәтле остабикәләр! Торыңыз! Қушылыңыз! бәңа ки, чиктән чығып хатыннарға җәберлек қыйлучы ирләрнең пинҗәсеннән һәмшәрәләремезне қотқармаға керешәлем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 362]; Киләлем мақсудымызыға [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 376]. Аңлашылганча, теләк фигыльнең традицион *-алем* формасы, мәгърифәтчеләр иҗатында кабул ителгән тәртибен саклаган хәлдә, ягъни вакыйга барышын җитәкләү һәм персонаж исеменнән мөһим бер фикерне әйттерү өчен файдаланыла.

Классик әдипләрнең беренче хикәяләрендә үк теләк фигыльнең күрсәткечләре татар халкының җанлы сөйләмә нормасына күчерелә, ягъни теләк фигыльдәге зат кушымчасының тар язылыштагы варианты кулланыла. Мәсәлән, Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясендә: Мин тәнкәләремне рәһен сақлауға куйып алыйм ...дүрт-биш көн элек анда булыйқ. ...Алла насыйп итсә, Қазанға илтергә келим [Исхакый, 1998, б. 33]; Йа Раббем, аларға ничек доға қылыйм. ...әбиләргә, бабайларға Қоръән уқып килим [Исхакый, 1998, б. 37]. «Кәләпүшче кыз»да: Камәр берлә Wафаның ни сөйләгәннәрен, ни эшләгәннәрен уқучыларға қалдырып, Кәримәләрнең өйенә қайтыйқ [Исхакый, 1998, б. 64]; Фәхри абый, тизрәк барыйқ инде [Исхакый, 1998, б. 119]. «Ике йөз елдан соң инкыйраз»да: Уқыйм, белим, дөньйада торыйм, башқалар торғанны қарыйм, бергә торамыз дип ыжғырып тора торган балаларға... [Исхакый, 1998, б. 209] һ.б.

Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) әсәрендә: Йахшы, алайса, без тәфсир, хәдистән сорап қарыйқ. ...менә без сезгә бер китап биреп қарыйқ, белерсезме икән... [Ибраһимов, 1974, б. 422]. «Яз башы» (1910) хикәясендә: Йә, ...тизрәк чабыйқ [Ибраһимов, 1974, б. 61]. «Яшь йөрәклер» (1912) романында: Сез, мөнбәрдә исемен әйттереп, дан чығарырға теләгән башқорт ағайның қыйссасын ишеткәнеңез бардыр. Булмаса, сөйлик [Ибраһимов, 1975, б. 30].

Ф. Әмирханның «Кадерле минутлар» (1912) хикәясендә: Қадерле минутларымның берсен, иң әүwәлгесен, әфәнделәр, мин сезгә сөйлим [Әмирхан, 1984, б. 106]; Йук, торыйқ әле бераз. Монда шундый матур, шундый рәхәт, торыйқ әле, Алечка, бераз [Әмирхан, 1984, б. 109].

«Фәтхулла хәзрәт» повестенда: Әйдә әле, мәсәлән, мелла кем, теге йаққа чығыйқ әле [Әмирхан, 1985, б. 60] һ.б.

Башка каләмдәшләреннән аермалы буларак, М. Гафури әсәрләрендә I зат хәзерге заман хикәя фигыль дә, теләк фигыль дә, кагыйдә буларак, киң язылышта, ягъни *-айым, -айык* кушымчалары белән файдаланыла. «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» (1904) хикәясендә: Мин қайдан беләйем, қайдан күрәйем... [Гафури, 1983, б. 9]; Ай Аллам,ниләр эшләйем икән [Гафури, 1983, б. 12]. «Ачлык ел, яки сатлык кыз» хикәясендә: Балам, ничек итәйем соң [Гафури, 1983, б. 20]; ...күрше хатыны Хәсбине чақырып кил, азрақ сүзләшеп утырайым [Гафури, 1983, б. 23]. «Үги балалар» (1908) хикәясендә: Урыны илә шуны да әйтеп китәйем әле... [Гафури, 1983, б. 40].

М. Гафуриның әлеге әсәрләрендә, хикәя һәм теләк фигыльләрнең тар язылышы белән бирелгән кайбер өзекләр күзәтелүгә карамастан, мисаллардан күренгәнчә, киң язылыш төре шактый еш кабатлана. Әлеге күренешкә үз вакытында Г. Тукай да игътибар итә, кире мөнәсәбәт белдерә, С. Сүнчәләйгә язган хатында бодай ди: ...Мин ...Мәҗит Ғафуриның «булмый» урынына «булмайларын» терпеть не могу... [Тукай, 1986, т. 5, б. 95].

Шулай итеп, сәнгатьле проза әсәрләрендә, теләк фигыльнең синтетик төре язылышында, җанлы сөйләмә норма өстенлек ала һәм әдәби тел берәмлеге булып күтәрелә.

Өйрәнелә торган чорда мәгърифәтчеләр иҗатында да, классик әдипләр иҗатында да хәзерге әдәби тел нормасы булып саналган, шулай ук җанлы сөйләмгә дә хас булган *-магае, -гыры* формалы теләк фигыльләре актив кулланыла дип әйтеп булмый. Мәсәлән, Г. Исхакыйның «Кияү» хикәясеннән бер мисал китерергә мөмкин: Атларны қауларға туғры килсә, дорфа иттереп, сүгенеп қычқырма... Алланын рәхмәте төшкере, һайә – дип кенә қычқыр, – диде [Исхакый, 1991, б. 242]. Әлеге формалар Г. Ибраһимов иҗатында чагылыш таба башлый. Мәсәлән, «Яшь йөрәкләр»дә: – Крәстийән булмағайы, қадалып китсен... Мин аны балам булмағайы, аллам булса да, үз ирегем белән аwылғ қайтарып, үз күз алдымда чабаталы крәстийән-мужик булып йөргәнен күрер хәлем йуқ... [Ибраһимов, 1975, б. 59]; ...чуқынсынлар ла, каһәр төшкәрләре... [Ибраһимов, 1975, б. 59] һ.б.

Теләк наклонениесен белдерә торган берничә морфологик чараның бергә генә калдырылуы һәм *-мак* күрсәткечле ният фигыльнең

шәхси теләкне белдерә торган аналитик формаларының да (*-мак иде, -мага эстәү* һ.б.) пассивлашуы нәтиҗәсендә, җанлы сөйләмдә теләк төшенчәсен белдереп файдаланыла торган аналитик төзелмәләргә, әдәби-язма тел күренеше буларак та, активлашуга юл ачыла. Бу күренеш бигрәк тә, киләчәк заман сыйфат фигыле *-асы* белән төрле ярдәмлекләргә нигезләнгән һәм, өлешчә, *-гы иде, -ырга* иде кебек аналитик формаларның кулланылуында чагылыш таба.

Алга таба *-магае, -гыры* формалы теләк фигыльләр дә әдәби тел берәмлеге буларак кулланыла башлый.

Хәзерге вакытта барлык төрки телләрдә дә актив кулланыла [Юлдашев, 1965, с. 109), татар әдәби телендә [Татарская грамматика, 1993, 2, с. 148–149] һәм аның барлык диалектларында да [Юсупов, 1986, с. 216] киң файдаланыла торган *-асы кил-* аналитик теләк фигыль эзлеклерәк булып, Ф. Кәрими әсәрләрендә кулланыла башлый. Мәсәлән, «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә: Нә чара, кем қызлары икәнлеклерене бик беләсем килсә дә, мөмкин булмады [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 227]. «Җиһангир мәхдүмнең ауыл мәктәбендә укуы» әсәрендә: Хәзрәт мөмкин мәртәбә ғыйлемне күбрәк таратасы килә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 231]; Шинбә көн атасы барырға қуша, ләкин баланың барасы килми [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 237]. Мисаллардан аңлашылганча, *-асы кил-* аналитик теләк фигыль I һәм III затларга нисбәтле теләкне белдерә, сыйфат фигыль мәгънәсендә дә файдаланыла. Бу форманың әлеге мөмкинлекләре үз вакытында бер-ике мәртәбә К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда файдаланылганнан соң (Падишаһ дәхи, бу эшнең хикмәтен бик беләсе килеп, сарайны халwәт қалдырыйқ ...сарайдан чығарды, [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 210]), Ф. Кәрими һәм Г. Исхакый иҗатларында активлаша. Г. Исхакый әсәрләрендә *-асы иде, -ырга кели, -ырга тели* формалары да теләк-ният мәгънәсендә кулланыла башлый. «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясендә: Кеше белүе безгә түгел, әнә шул, шуңарға қызығып уқытырға келисең [Исхакый, 1998, б. 32]; И Әсма абыстай, бик җибәрергә телим дә, үзенең дә бик барасы килә... балаңа фарыз булған ғыйлемне үгрәтергә келисең. ...қайа илтергә келисең? ...Қазанға илтергә келим [Исхакый, 1998, б. 33]. «Кәләпүшче кыз»да: ...анасы хәзер иргә китәргә хәзерләнә торған булғанға, анда чығып үзенең исемен йуғалтасы килми иде [Исхакый, 1998, б. 55]. «Очрашу яки Гөлгыйзар»да: Теге абыстайға үзенең менәсе килми иде, әмма күрәсе килә иде [Исхакый, 1998, б. 107] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, *-асы кил-, -ырга кели, -ырга тели* формалары әдипнең персонажлары сөйләмендә ешрак кабатлана. «Бай угылы» повестенда: Минем барасым да килми, әллә бармыйкмы? [Исхакый, 1998, б. 118]; Белмим, барасың килсә алырсың. ...Минем бик эчәсем килә шул [Исхакый, 1998, б. 120] һ.б. Аналитик төзелешле теләк фигыльләр Г. Исхакыйның драма әсәрләрендә дә еш кабатлана. Әлеге аналитик формалы теләк фигылләре белән бергә, синтетик формалы *-ыйм, -ыйк* кушымчалы теләк фигыльләре дә кулланылуда була, әмма аналитик формалы теләк фигыльләре җанлы сөйләмгә якын итеп язылган текстларда ешрак файдаланыла. Бу үзенчәлек башка әдипләр иҗатында да дәвам ителә. Мәсәлән, М. Гафуриның сәнгатьле прозасында: Эчәсең килсә, қуй да эч, қулың бар ич [Гафури, 1983, б. 11]; Бары бер мәртәбә шәлемне күтәреп, бер генә қарадым. Қайта күрәсем килмәде [Гафури, 1983, б. 15].

Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында: Шуның өчен ул бу көн ахирәтенә эчендәге бар нәрсәсен түгәсе килә [Ибраһимов, 1975, б. 24]; Һәрнәрсәне үзенә генә аласы килә [Ибраһимов, 1975, б. 31] һ.б.

Ф. Әмирханның «Танымаганлыктан таныштык» хикәясендә: Аны әллә нинди бер мәләки (фәрештәwи) сөйү белән сөйәсем килә башлады [Әмирхан, 1984, б. 61] һ.б.

*-асы килә иде* ярдәмлеге белән кулланылган вакытта, теләк мәгънәсен үткәнгә күчерү белән бергә, хикәяләү барышын саклау вазифасы саклана. Ф. Әмирханның «Хәкарәт саналган мәхәббәт» хикәясендә: Салих шул «йук» ны қат-қат уйлап, үз-үзен «йук» икәнчелегенә ышандырасы килә иде йук [Әмирхан, 1984, б. 29] һ.б. Г. Ибраһимовның «Яз башы»нда: Бүген минем гел чабасым, чаптырасым ғына килә, атлап йөрүне бөтенләй оныттым. Тәнемдә тиремә сыймаған бер көч, бер дәрт бар төсле: сикерәсе, дулыйсы, әллә нинди бийек җирләргә менәсе, еғыласы килә иде [Ибраһимов, 1974, б. 54].

Өйрәнелә торган чорда язылган текстларда, *-асы килә* төзелмәле теләк фигыль белән бергә, тагын бик үк актив булмаса да, *-асы бул, -асы иде, -асы икән, -ырга иде* формаларының да кулланылуы күзәтелә. Мәсәлән, «Кырык вәзир» кыйссасында: Ул көнче кеше әйтте: Әгәр сиңа патша йәшертен сүз әйтәсе булса, сақлан сарымсақ исен сиздермә [Насыйри, 1975, б. 235]. Г. Исхакыйның «Зиндан» әсәрендә: Ә, әле синең йалғыз бүлмәдә утырасың килә икән! [Исхакый, 1998, б. 323]. Ф. Әмирханның «Танымаганлыктан таныштык» хикәясендә: Былтыр җәй көне эти әйтә: уғылым, ди, син, имтихан биреп, дуктыр буласы

идең ди [Әмирхан, 1984, б. 77]. Ф. Әмирханның «Кадерле минутлар» әсәрендә: Әнидән сезнең монда киләсе икәнегезне ишеткәч тә, әллә нишләп, сабырсызланып көттем мин сезне [Әмирхан, 1984, б. 135]. Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында: Тағы бераз уқырға да, хәлфә булырға да, менә, алла бирсә, зур бер урынға утырырға ғына иде... һич булмаса, атасын уйларға иде [Ибраһимов, 1975, б. 52] һ.б.

Беренче драма әсәрләрендә *-айым* һәм *-алем* формалы теләк фигыльләренең кулланылышында сизерлек дәрәҗәдә эш бүленеше күзәтелә. Мәсәлән, Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» (1888) драмасында эзлекле булып *-ыйм, -им* күрсәткечле теләк фигыльләре файдаланыла: ...бераз йоқлыйм дип, пич башына менеп йатқан иде [Халиди, 1888, б. 2]; И Сәлимә, син сорама, мин әйтмим [Халиди, 1888, б. 3]. Ә инде «Морад Сәлимов» (1905) драмасында автор, үзенең идеалы булган укымышлы, зыялы персонажларны тасвир иткәндә, теләк фигыльнең *-алем* формасы урынлы булыр дип саный, монда, *-айым, -айык* кушымчалары белән бергә, *-алем* күрсәткече ешрак кабатлана: Тамақ қыйлмаға wақыт җиткән, барып тамақ итәйем, соңра бу кичә бақча кафе-шантанға барайым [Татар әдәбияты, 1957, б. 597].

Г. Исхакыйның беренче драмаларында теләк фигыльнең традицион формалары күзәтелми, җанлы сөйләмгә хас булган күрсәткечләре генә кулланыла. Әлеге драмаларда күзәтелә торган теләк фигыль формасы, җанлы сөйләмдәгечә, ягъни, хәзерге әдәби тел өчен норма булып күтәрелгән рәвештә генә файдаланыла һәм башкаларында шул рәвешчә дәвам ителә.

*Кыскача нәтиҗәләр.* XIX гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән төрле жанр-стильдәге текстларда синтетик төрдәге *-ай, -ый, -әй, -и* формалы теләк наклонениесе I зат берлектә, киң һәм тар язылыштагы *-айын, -әйен, -айым, -әйем, -ыйм, -им* һәм күплек санда *-алем, -айык, -әйек, -ыйк, -ик* кушымчалары белән тәгъбир ителә. Димәк, теләк фигыль, өйрәнелә торган чорда, угыз һәм кыпчак телләренә хас булган ике әдәби тел нормасында яшәештә була. Шуның белән бергә, бу фигыльнең аналитик формалары да актив кулланылышта була.

Морфологик вариантлылык дигәндә, I зат өчен генә тәгаенләнгән бу фигыльнең функциональ-семантик кырының катлаулы булуы истә тотыла.

Татар прозасында хикәяләүнең беренче төрендә язылган кыйссаларда *-айым, -әйем, -ыйм, -им* формалы теләк фигыль эзлекле кулланыла.

Татар прозасында хикәяләүнең икенче төрендә язылган хикәя һәм романнарда *-алем, -айым, -ыйм* формалары персонажлар сөйләмендә дә параллель файдаланыла.

Классик әдипләр иҗатында әлеге форма һәм аларның вазифалары татар халкының җанлы сөйләмә нормасы белән алмаштырыла, ягъни теләк фигыль сүз нигезендәге сузыкка бәйле булган *-ыйм, -им, -ыйк, -ик* вариантлылыгын хасил иткән, тар язылыштагы формасы белән генә сакланып кала.

Теләк наклонениесен белдерә торган берничә морфологик чараның бергә генә калдырылуы һәм *-мак* күрсәткечле ният фигыльнең шәхси теләкне белдерә торган аналитик формаларының да (*-мак иде, -мага эстәү* һ.б.) пассивлашуы нәтиҗәсендә, теләк төшенчәсен белдереп җанлы сөйләмдә файдаланыла торган аналитик төзелмәләргә, әдәби-язма тел күренеше буларак та, активлашуга юл ачыла. Бу күренеш, бигрәк тә, киләчәк заман сыйфат фигыле *-асы* белән төрле ярдәмлекләргә нигезләнгән һәм, өлешчә, *-ырга тели, -ырга иде* кебек аналитик формаларның кулланылуында чагылыш таба.

Алга таба *-магае, -гыры* формалы теләк фигыльләре дә әдәби тел берәмлеге буларак кулланыла башлый.

Синтаксик вариантлылык дигәндә, аналитик формадагы теләк фигыльләрнең төрләре истә тотыла. Әлеге формаларның файдаланылуында, билгеле бер дәрәҗәдә, эш бүленеше күзәтелә, ягъни төрле жанр-стильдә язылган текстларда алар төрле ешлыкта кабатлана һәм хронологиягә бәйле рәвештә дә активлык һәм пассивлыкларын үзгәртәләр, шулай итеп, функциональ-стилистик вариантлылык барлыкка килә. Мәсәлән, *-айын* һәм *-алек* формасы, нигездә, Ә. Уразаев-Кормаши кыйссаларында, аларның да аеруча тезмә өлешләрендә, чагылыш таба.

*-алем* формасы сәнгатьле сөйләмнең барлык жанрларында да файдаланыла, мәгърифәтче әдипләр иҗатында әдипнең укучысына эндәшеп, сюжетны алып бару, ягъни хикәяләү барышын җитәкләү чарасы буларак күтәрелә һәм шулай ук, драма әсәрләрендәге кебек, персонажларның үзара сөйләшүендә билгеле бер нәзакәтлелек төсмерен белдерә, шулай итеп, югары стиль чарасы булып әверелә, Г. Тукай иҗатында исә, борынгылыкны сурәтләү чарасы буларак, махсус сайланып алына.

*Шарт фигыль.* Хәзергә татар әдәби телендә сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерә торган модальлек ка-

тегориясенең бер күрсәткече булган шарт наклонениесе (кондиционалис) икенче бер эшнең үтәлүенә шарт булган эш яки хәлне II төр (кыска) зат кушымчалары ала торган *-са, -сә* күрсәткечләре белән белдерә дип аңлатыла һәм төп фигыль белән мөнәсәбәтендәге мәгънә төсмерләре бик тәфсилле итеп тикшерелә [Татар грамматикасы, 2002, б. 157–164]. Татар диалектларында да шул ук кушымчалар белән нинди вазифа үти алулары анализланып күрсәтелә [Юсупов, 2004, с. 512–527].

Гомумтюркологик хезмәтләрдә *-са, -сә* кушымчасының, төрле вариантларда (башкорт телендә, *-һа, -һе*) һәм тарихи планда караганда, *-сар, -тар* тулы формадан кыскарып, үзара бәйле булган, боеру, теләк, ният, кирәклек, киләчәк заман хикәя фигыле һ.б. төрле мәгънә кулланыла алуы, абстрактлашып шарт фигыль мәгънәләрен бирүгә җайлашуы турында мәгълүмат бирелә [СИГТЯ, 1988, с. 347–356]. Шул ук гомумтюркологик яссылыкта шарт фигыльнең аналитик формалары җентекле рәвештә барланып, өйрәнелгән [Юлдашев, 1965, с. 232–245].

Татар телен фән буларак өйрәнеп язылган беренче хезмәтләрдә дә шарт фигыльгә игътибар ителә. Г. Фәезхановның «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» (1887) китабында «фигыль шартына» түбәндәгечә аңлатма бирелә: «Фиғыль шарт диб шундай фиғыльне әйтәләр ки, ул фиғыльнең булуы икенче бер фиғыльгә тәвәққыф қыйлыр (тукталыр)» [Фәизхан, 1887, б. 24].

К. Насыйриның «Әнмүзәҗ» (1895) хезмәтендә дә шарт фигыльгә шундый ук аңлатма бирелә, әлеге фигыльнең *иде* кәлимәсе белән берлектә дә кулланылып теләкне белдерә алуы ассызыклана: *йазсам иде, йазсаң иде, йазса иде* һ.б. Бу галим шарт фигыльне хәзерге, үткән һәм киләчәк заманнарда булырга мөмкин дип уйлый: *йазсам, йазган булсам, йазар идем* [Насыйри, 1975, б. 75–76].

М. Өметбаевның «Татар нәхүсенең мохтәсары» (1901) дәреслегендә *-са* кушымчалы фигыльләр бер үк вакытта хәзерге һәм киләчәк заманга да йөри дип, киләчәкнең шартын *йазсам кирәк* тезмәсе дә белдерә дип аңлата, һәм шартка бәйле рәвештә бу дәреслектә тагын түбәндәге тезмәләр дә бирелә: йаза торған булсам, йазған булсам, йазсам иде, йазған булсам иде, йаза торған булсам иде [Өметбаев, 1901, б. 29–32]. «Языки мира: Тюркские языки» дигән энциклопедик хезмәттән аңлашылганча, һәм борынгы, һәм хәзерге телләрдә шарт наклонениесенең кулланылышта булуы теркәлгән [Языки мира..., 1997, с. 43, 59, 68, 122] һ.б. Ә.Н. Нәҗип һәм Г.Ф. Благова язган «Тюрки язык» дигән мәкаләдә шарт фигыльнең хәзерге заманы *-са,* үткән заманы *-са и(р)де*

кушымчасы белән, соңгы кушымчаның сослагательное наклонениенең (шартлы теләк) күрсәткече дә булуы билгеләнә [Языки мира..., 1997, б. 133]. Шул ук фикер Э.И. Фазылов мәкаләсендә кабатлана, М.З. Зәкиев тарафыннан язылган татар теле турындагы мәкаләдә, *-са* кушымчалы шарт, *-ыр иде* кушымчалы шартлы теләк фигыльләре белән рәттән, ният, кирәклек, мөмкинлек һ.б.модальлекләрнең күрсәткечләре дә билгеләнә [Языки мира..., 1997, с. 364]. Л. Җәләй «Татар теленең тарихи морфологиясе (Очерклар)» хезмәтендә, шарт фигыльнең төп күрсәткече булган *-са* кушымчасының, тарихи яссылыкта караганда да, синтетик һәм аналитик формаларда кулланылуын күп санлы мисаллар белән аңлата [Җәләй, 2000, б. 224–233].

Академик басма булган «Татар грамматикасы»нда һәм «Татар теле морфологиясе» дәреслегендә [2006, б. 199–205], шарт фигыльнең реаль шарт, фаразый шарт, ирреаль шарт, кире шарт, шартлы теләк дигән мәгънәләре буенча тикшерелүе барышында, һәр шартның төп-нигез формасын билгеләп, шарт фигыльнең синтетик формасы белән бергә, барлык аналитик формаларын да, шул исәптән шартлы теләк күрсәткечен дә, бергә карарга мөмкин булуы күренә. Шул ук вакытта, шарт фигыль формаларының башка мәгънә белдерә алуы, яисә башка фигыльләрнең шарт фигыль вазифасын үти алуы кебек катлаулы мәсьәләләр аңлатыла.

Татар язма истәлекләрен тикшерүчеләрнең хезмәтләрендә, өйрәнелә торган чыганакта файдаланылган шарт фигыльнең формалары барлана, аларның нинди мәгънә белдерүе һәм аерым авторлар тарафыннан заманга мөнәсәбәте күзаллана [Нуриева, 1977, б. 136; Ахметгалеева, 1979, с. 99; Хисамова, 1990, б. 81; Исхакова, 2005, б. 141–144; Юсупов, 2006, с. 10–108; Мирхаев, 2007, с. 112–115; Гайнуллина, 2010, б. 152–160; Миннуллин, 2012, с. 186–189] һ.б. Шарт фигыльнең XIX гасыр – XX йөз башында төрле жанр-стильдә язылган текстларда кулланылышын өйрәнү дә әлеге юнәлештә барачагы аңлашыла.

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә (1845, 1889): ...Диде: ...Нулә ки, замм әйләсәң, бер илкеңә дотсаң бәһәм / ...Нулә йәд әйләрсәң Аллаһ исемене... Ул кәримә диде: ...икесен замм әйләр ирсәм, күп улыр [Каргалый, 1889, б. 2]. Димәк, II зат синтетик *-әйләсәң, әйләрсәң,* I зат аналитик *-әйләр ирсәм* формалы шарт фигыльнең нәтиҗәсе, традицион *-р,* хәзерге телдә *-а* күрсәткечле хәзерге заман белән реаль шартның гадәтилеген бел-

дерә: Қатғ идеб базарда йисә һәр кеше / Тохымыны җәмғ әйләмәк ирде эше (җыю иде) [Каргалый, 1889, б. 3]. Әлеге җөмләдә III зат синтетик *-йисә (ашаса)* формалы шарт фигыльнең нәтиҗәсе, *-мак ирде* (хәзерге әдәби телдә *-у иде*) гадәти үткән заман белән реаль шарт белдерелә. Түбәндәге җөмләдә *-улса, -рсан* формаларының мөнәсәбәте аша реаль шарт белән белдерелгән мәгънәнең киләчәктә төзәтелүен өмет итү, үтенү мәгънәсе бирелә: Ул Хәбибнең хөрмәтенә, йә Илаһ / Кәчүрәсән, бездән улса, һәр гөнаһ [Каргалый, 1889, б. 3].

*-са/-р ирде* күрсәткечле: а) шартлы теләк мәгънәсе: ...Хәшр-үнәшрә әйләр ирсәк иқтиқад / Әхирәтчөн әйләр ирдек куәт-зад [Каргалый, 1889, б. 4] һ.б.; ә) шарт-нәтиҗә мөнәсәбәте: ...керсә анда бер хәстә-ғариб, улыр иде шул заманда сихәти [Каргалый, 1889, б. 8]. Бу җөмләдә реаль шартның киләчәктәге гадәтилеге тәмамланмаган үткән заманның *-р иде (-а иде)* кушымчасы белән бирелә.

*-саңыз/-урым* күрсәткечле шарт-нәтиҗә мөнәсәбәте: Шөкер идәрсәңез сезләр бәңа әгәр / Артдырурым ниғмәтне сәрбәсәр [Каргалый, 1889, б. 9]. Бу җөмләдә реаль шартның киләчәктәге гадәтилеге II зат күплек сандагы шарт фигыль I зат берлек сандагы *-р (-а)* формалы фигыль белән белдерелә.

*-са/-маз* күрсәткечле шарт-нәтиҗә мөнәсәбәте кире шартны белдерә: Һәфтәдә, айда кәлирсә бер фәқыйрь / Улимазыз аңа дәхи дәстгир (Бу атнада бер фәкыйрь килсә, аңа ярдәм итә алмыйбыз) [Каргалый, 1889, б. 3]; ...Диде: Бер кемсә бу миқдар ғыйбадәт / Идеб, ахырда һәм тапса шәһадәт / Бәнем өммәтләремдә бу фазыйләт / Улынмаз», – дәйү килде аңа көрбәт (Бер кеше бу кадәр гыйбадәт итеп, ахырда таныклык тапса, Минем өммәтләремдә бу өстенлек булмас, дип килде аңа үкенеч) [Каргалый, 1889, б. 7]. Шул ук кире шарт мәгънәсе *-са/-маз ирмеш* күрсәткечле шарт-нәтиҗә мөнәсәбәте белән дә белдерелә: ...Уйла улса, Хақ эшә мөнкәр кеше / Уңмаз ирмеш ике галәмдә эше (Хак эшенә гөнаһ кеше булса, ике галәмдә эше уңмас икән) [Каргалый, 1889, б. 11].

Шарт мәгънәсе тагын *-ыр+мәгәр* формасы белән белдерелә: Шәйи Алла эстәю килер мәгәр, / Вирер аңа эстәдекендин зийад (Алладан теләп килсә, теләгәненнән күп бирер) [Каргалый, 1898, б. 3] һ.б.

Шулай итеп, Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәрендә шарт фигыль *-са, -саң, -саңыз әгәр, -рсаң, -р ирсәм* формаларында, нәтиҗәсе *-р, -мак иде, -ырсан, -р ирде,-ыр, -маз, -маз ирмеш* күрсәткечләре белән, шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтенең гадәтилеге,

яисә киресе бирелә. Шарт фигыль вазифасы *-ыр + мәгәр* кушымчасы белән белдерелә.

Һ. Салиховның «Китабы мәҗмәгыль адәб» (1856, 1900) җыентыгында, дини-дидактик үгетләүләр белән бергә, көндәлек тормыштагы аерым кешеләрнең, бигрәк тә үзен галим, мулла дип санаганнарның, мәрхәмәтсезлеген күрсәтә торган өзекләрдә, әлеге эшләрнең нинди шартларда баруы тасвирлана. «Замана хакиме охшар йыланға...» дип башланган өзектә бу ачык чагыла: ...Хатаңа улсалар wақыйф бер эштә: / Кавелдә, йә фиғыльдә, йә йөрештә. / Хатаңны ғамдеңә хәмел итәрләр / Ки wәһми катғый эштән ғадь итәрләр / Шу дәклү итәрләр тәфтиштә диққать / Ишарәт-рәмзене итмәйеп фәвет... [Салихов, 1900, б. 16]. *-улса* кушымчалы бер шарт нигезенә, *-р* күрсәткеченә тәмамланып, өч мәртәбә кабатлана торган тезмә хәбәр бирелә, ягъни шарт-нәтиҗә мөнәсәбәте *-са/-р* формалары белән гадәти, кабатлаулы эш-хәлләрне белдерә. Шарт һәм нәтиҗә фигыльләре бер үк санда булырга мөмкин: ...Дөшерсә, әлләренә бер нәмәрсә / Дәраһимнән wә йә динардан улса... / Сәйәсәт сақыйт улыр, бағланыр тел (Гаепләнүче кеше көмеш яки алтын бирсә, хакимнең ачуы кими, җәза ташланыр, тел багланыр). *-са* кушымчалы ике шарт фигыльгә, *-р* кушымчалы ике хәзерге-киләчәк фигыле туры китерелә. Кире шарт мөнәсәбәте дә шулай төзелә: Җәбәл тик ғайби күрсә, телгә саймаз / Кәбаир күрсә ул, бер шәйгә санмаз (Акча биргән кешенең таудай гаебен күрсә дә, телгә алмый, Олы кешене бер нәрсәгә дә санамый) [Салихов, 1900, б. 17]. Әмма шарт фигыльгә каратылган хәзерге-киләчәк заман фигыльләре күбрәк булган очраклар ешрак күзәтелә, авторның мөнәсәбәте тулырак сурәтләнә.

Г. Кандалый шигырьләрендә шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтенең төрле мөмкинлеге файдаланыла. *-са/-р(-маз), -р булса/-маз ирде* күрсәткечләре мөнәсәбәте белән реаль шарт белдерелә: Бәне сәүми дийеп әйтсәң, телең қорыр / Бәне ташлап йатка китсәң, Ходай орыр [Кандалый, 1988, б. 111]; ...Җәмалеңә төшәр булса күзем турый / Шул заманда сабрым қарар қыйлмаз ирде [Кандалый, 1988, б. 111] һ.б.

*-р булсаң* формалы шарт фигыль берничә мәртәбә кабатлана, *-гыл* боерык фигыле нәтиҗә җөмләдә бер мәртәбә бирелә, аларның мөнәсәбәте белән реаль шарт белдерелә: Әйа йил, сән китәр булсаң / Фәлян йиргә йитәр булсаң / Туғанымны күрәр булсаң / Доға дигел ки безләрдин [Кандалый, 1988, б. 88]. Шул ук мәгънә *-са* / нуль формалы боерык фигыль мөнәсәбәте белән белдерелә: ...Килер булсаң, и мату-

рым, сеңелкәй / Сүземне тыңла, қалдырма күңелкәй [Кандалый, 1988, б. 151]. Шул ук мәгънә *-са/-ың* формалы боерык фигыль белән: ...Ки бәгъзеләр надан булса / Ғалимләргә қоллық қыйлса / Тәғәт, қоллықны күп қыйлса / Ғалимләрдин сайуң аный [Кандалый, 1988, б. 177]. Шул ук мәгънә *-са/-ыйм (имди)* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләренең мөнәсбәте белән белдерелә: ...Сәнең буйың, җанекәйем, зифа үссә / Бәнем йөрәк-бәғыремне шулар киссә / Иртә торсам, сезнең йақдин җилләр иссә / Шул җилләрдин исәнлегең сорыйм имди [Кандалый, 1988, б. 113]. Димәк, реаль шарт мәгънәсе *-са/-р(-маз), -р булса/-маз ирде, -са/нуль, -гыл, -ың* күрсәткечле боерык фигыль, *-ыйм (имди)* күрсәткечле хәзерге-киләчәк заман фигыле белән күрсәтелә.

*-са/-р имди* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләренең мөнәсәбәте белән фаразый шарт белдерелә: ...Шуны йазып йибәрсәм имди хатларға / «Менә қәһәр доға төшде!» дирсең имди [Кандалый, 1988, б. 114]. Шул ук мәгънә *-әгәр -са/-сың* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләрнең мөнәсәбәте белән белдерелә: ...Бән әгәр күрешәйен дисәм, / Шайәд әллә ойаласың / Ойалмақың чын булса гәр / Зәһи (бик) инсафлы баласың [Кандалый, 1988, б. 138]. Фаразый шарт шулай ук *-р булса/-р иде* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләренең мөнәсәбәте белән дә белдерелә: Асыл қошны тотар идем / Тирәк төбенә лә қунса / Сағәт сайын күрәр идем / Сән җаныйдин әмер булса [Кандалый, 1988, б. 146] һ.б.

*-са(-гәр)/-а (иде), -мас иде* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләрнең мөнәсәбәте белән ирреаль шарт мәгънәсе белдерелә: Кеше үзүзенә салса бәла / Җиһан халқы җыйылса, белмәс ала [Кандалый, 1988, б. 165]. Бу мисалда *ала* сүзенең рифма өчен генә кулланылуы *иде* ярдәмлеге белән алмаштырырга мөмкинлек тудыра. ...Ки Хақ йазмаса(гәр) бән азмас идем / Ул сүзеңезгә бән хат йазмас идем [Кандалый, 1988, б. 197] һ.б.

*-са/-мый, -исә дә/-р исә дә, -масын* шарт-нәтиҗә фигыльләрнең мөнәсәбәте белән кире шарт мәгънәсе белдерелә: Қаләм алсам, йазып булмый / Мөқәддәрдин (тәкъдирдән) узып булмый [Кандалый, 1988, б. 91].

Шарт фигыльнең башка мәгънәләрдә кулланылуы күзәтелә. Күрелеп үткән хикәя фигыль мәгънәсендә: Сөйеп бу илгә килсәм дә, / Ки йурға кеби җилсәм дә / Бөтен вөҗүдем, ил, сәндә, / Нигә тиз мине йатсындың. Мантыйк буенча, *-сәм* кушымчасы урынына *-дым* кушымчасы көтелә. Икенче строфада шулай кулланыла да: Туған илем

йырақ қалды / Җәйәү йөреп сыйрақ талды / Тағы бигрәк йөрәк йанды / Әзәлдәген ник азсындың? [Кандалый, 1988, б. 75].

XIX гасырның икенче яртысында язылган поэзия әсәрләрендә дә шарт фигыльләрнең эзлекле рәвештә кулланылуы күренә.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Бүз йегет» әсәрендә (1874) *-са кирәк* тезмәсе II зат берлек сан формасында, эш яки хәлләрне башкарырга рөхсәт итү, киңәш бирү мәгънәсендә кулланыла: Без илеңә барғанчы, дидареңезни күргәнчә, / Лилә менән Мәҗнүндәй, сабыр қыйлсаң кирәкте. / Сабыр қыйлмай, эш бетмәс, морадиға тиз йитмәс / Зөләйха берлән Йосыфдай, сабыр қыйлсаң кирәкте / Барыр wақыт булған җуқ, булса, көн тулған йуқ, / Таһир менән Зөһрәдәй, сабыр қыйлсаң кирәкте... [Уразаев-Кормаши, 1874, б. 3] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә (1879): Аллаһе тәбарәкә wә тәғалә миңа бер фәрзәнд рузи қыйлса, мең алтын түгел, бәлки бөтен солтанатем бирсәм кирәкдер [Татар әдәбияты, 1957, б. 288]; Әгәр гүзәллекләрен бәйа қыйлсақ, бу китап қадәре дәхи бер китапны: ғалә хәддиһи йазсақ кирәк [Татар әдәбияты, 1957, б. 290].

Кыйссаның тезмә өлешендә генә түгел, чәчмә өлешендә дә күзәтелә: Инша аллаһе тәғалә хақ җәллә wә ғаллә хазрәтләре әҗәлдән әман биреп, монафыйқлар шәрендән сақласа, бу кич ғаләм айағы басып, сил булғанында барсам кирәкдер [Татар әдәбияты, 1957, б. 312] һ.б.

Әлеге форма, ягъни *-са* кушымчасы һәм *кирәк* модаль сүзе, III затка нисбәтән булганда, ышанычка төрелгән гөман итү мәгънәсе бирелә: Қыйәмәт көн ходайым безне қушса кирәкде, / Һәр йаралған бәндәгә хөкем қыйлса кирәкде... [Татар әдәбияты, 1957, б. 336].

Үзеннән-үзе аңлашылганча, әлеге кыйссаларда шарт фигыль үзенең башка мәгънәләре белән дә кулланыла, хосусый үзенчәлекләргә килгәндә, *-са кирәк* тезмәсе кебек актив булмаса да, *-гач* кушымчасы белән алмаштырылырга мөмкинлеге булган һәм төп фигыле киләчәк заман планында да куела торган *алай булса* тезмәле шарт фигыльне күрсәтергә мөмкин: ...Андан соң уртанчы қыз йәнә әйтде: Алай булса, мин үземне ғарыз қыйламын, әгәр дә қабул қыйлмаса, ағу биреп үтермен, – диде. Андан соң, моны ишетеп, олуғ қыз әйтде: Алай булса, мин һәм Таһирның айақ-қулын бәйләп, Шат суына олақтырырмын, – диде [Татар әдәбияты, 1957, б. 324].

*-са иде* тезмәсе теләкне белдерә: Болар ул қадәр гүзәл иде кем, бер кәррә йөзләрен күргән адәм, аһ, дәхи, бер мәртәбә күрсәм иде дип,

зар чигәр иде [Татар әдәбияты, 1957, б. 292]. II заттагы *-са* күрсәткече үтенүле теләкне аңлата: И солтаным, бераз сабыр қыйлып, ачмый торсаңыз ни булыр? [Татар әдәбияты, 1957, б. 303]. III заттагы *-са* күрсәткече хикәя фигыльнең күрелеп үткән вазифасында файдаланыла: ...дип тәрәзәдән қараса, ул кәрwаннарның урыннарыннан җилләр исәр [Татар әдәбияты, 1957, б. 309] һ.б.

*-са* кушымчасының вакыт мөнәсәбәтендә файдаланылуы XIX гасырның икенче яртысында язылган шигъри әсәрләрдә дә күзәтелә. Г. Чокрыйда: Ғали мискин, бу әбйатың қачан кем әзкийә күрсә, / Дийәрләр: «Чүб-саламдыр бу. Ничөн йазған ушал бәндә»... [Татар поэзиясе..., 1992, б. 334] һ.б.

М. Акмуллада: Қайда бер тәхқиқ күрсәм, қуанамын, / Бу затда ғәҗәб тәхқиқ күргәннән соң, / Биззарур шул сәбәбдән хуб аламын... [Акмулла, 2001, б. 12]; ...Бер шәрик қалын китаб остап торса, / Қызығып, мин фәқирнең күзе алаңдай [Акмулла, 2001, б. 12] һ.б.

Г. Тукай иҗатында шарт һәм аның нәтиҗәсен белдерә торган фигыльләрнең барлык төрләре дә тасвирлау чарасы буларак яратып кулланыла. *-са да* боерык фигыль шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтендә реаль шарт белдерелә: Тәнебез айырым булса да / Бер тән булыйқ, бәдәвам [Тукай, 1955, т. 1, б. 10]; ...Қарчығың қайда чақырса, шунда бар [Тукай, 1955, т. 1, б. 28].

*-са/-р(-а)* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләр мөнәсәбәтендә реаль шарт белдерелә: Намеңи тәхрир идәрсәм, фаш улыр дөньйайа раз (Исемеңне язсам, сер дөньяга фаш була) [Тукай, 1955, т. 1, б. 18]. «Театр» шигырендә: Үсәр йахшылығың, син йахшы булсаң, /Җылы қанлы итәр ул, вәхши булсаң... [Тукай, 1955, т. 1, б. 92].

*-са да/-ды* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләр мөнәсәбәтендә, реаль шарт белдерелә: Йурган йабып Йоқлап йаттық / Уйғанмадық, Таң атса да, / Уйланмадық! Бәхтемезнең Қояшы байып батса да [Тукай, 1955, т. 1, б. 62].

*-р исә* формалы хәзерге-киләчәк заман фигыльләр мөнәсәбәтендә реаль шартның гадәтилек мәгънәсе белдерелә: Кышлар үтеп, яз көнләре килер исә / Сахраларда йомшак саба җиле исә [Тукай, 1955, т. 1, б. 17].

*-са* хәзерге-киләчәк заман фигыльләр мөнәсәбәтендә реаль шартның гадәтилек мәгънәсе белдерелә: Қаршы әйтсә, йаңағына сөрткәли [Тукай, 1955, т. 1, б. 25]; ...Матур булыр бу қорсақларға қаршы чаралар қорсақ [Тукай, 1955, т. 1, б. 34].

Әлеге мәгънә белдерелгән вакытта аерым шигырьләрдә шарт фигыль эзлекле рәвештә кабатланырга мөмкин: «Татар кызларына» шигырендә: ...Ишан хәзрәт билет бирсә бәңа гәр, / Аның ла җәннәтә керсәм бәрабәр, / Бәнем қаршымда хур қалфақ кимәзсә, / Бәңа: «Җанашым, исәнме?» –димәзсә, / Дийәм, әстәғфирулла, анда кермим, / Китәм әғрафә тиз, бер ан да тормыйм [Тукай, 1955, т. 1, б. 37]. «Дөньяда торыйммы? – дип киңәшләшкән дустыма» шигырендә: Тормақ йарый: бертуқтамый йалғанласаң, / Туғры сүзле инсаннарға йалғанмасаң, / Вөҗданыннан шайтан төсле тыр-тыр қачып, / Үзең алдап, башкалардан алданмасаң... [Тукай, 1955, т. 1, б. 96] һ.б. Авторның «Китап» шигыре дә шушы ысул белән язылa, тик монда гадәти эзлеклелек мәгънәсе *-а* формалы фигыль белән белдерелә: Һич тә күңлем ачылмаслық эчем пошса, / үз-үземне күралмыйча, рухым төшсә / Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны / қуйалмыйча җанға җылы һичбер төшкә; / ...Шул wақытта мин қулыма китап алам / Аның изге сәхифәләрен ақтарам, / рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем, / Шуннан ғына дәртләремә дәрман табам... [Тукай, 1955, т. 2, б. 35].

*-са/-ирде (-р иде)* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләр мөнәсәбәтендә фаразый шарт белдерелә: Фараз иттем: Рәсүлулла терелсә, / Мөбарәк җисменә гәр рух өрелсә, / Сези ул, шөбһәсез, тәбрик идәрди, / Сези тәшвиқ идәр, тәхрик идәрди [Тукай, 1955, т. 1, б. 60].

*-са да/-ды* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләр мөнәсәбәтендә кире шарт мәгънәсе белдерелә. «Туган илемә» шигырендә: Айырылып китсәм дә синнән, ғомремең таңында мин / И Қазан арты! Сиңа қайттым сөйеп тағын да мин / ...Қысса да синдә йәтимлекләр, фәқыйрьлекләр мине / Изсә дә үз ишләремнән хур wә кимлекләр мине / Үтте инде ул заманлар, очтылар шул қош кеби / Уйласам, ул көннәрем тик кичтә күргән төш кеби [Тукай, 1955, т. 1, б. 80] һ.б.

*-са да/-ган иде* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләр мөнәсәбәтендә кире шарт мәгънәсе белдерелә. «Шүрәле» поэмасында: Гәрчә анда туғмасам да, мин бераз торған идем, / Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урған идем... [Тукай, 1955, т. 1, б. 83].

Г. Тукайның күп кенә шигырьләрендә шарт фигыль вакыт мөнәсәбәтен, вакыйгаларның эзлеклелеген белдерү мәгънәсе белән кулланыла. «Пар ат»та: Бер заман ачсам күзем, бер төрле йап-йат қыр күрәм, / Аһ, бу нинди айырылу? Ғомеремдә бер тапқыр күрәм... [Тукай, 1955, т. 1, б. 81]. «Тормыш»та: Аwырлық төшсә, түз, сер бирми-нитми, / Ни хәлләре йәшь йегеткә килми-китми [Тукай, 1955, т. 1,

б. 151]. «Мулланың зары»нда: Сүз дәшүче йуқ иде, мин бер қараны ақ дисәм, / Һай ғомерләр, Әһле исламға итағать бар иде [Тукай, 1955, т. 1, б. 164] һ.б.

Г. Тукайның күп кенә шигырьләрендә *-са* кушымчасы кабатлаулы тотрыклы тезмәләрдә файдаланыла: ...әйтсәм әйтим инде сезгә: бу кеше бик бай иде [Тукай, 1955, т. 1, б. 74]; ...һич ғаҗәп йуқ, булса булыр, бик қалын, бик күп бит ул [Тукай, 1955, т. 1, б. 84]; ...Күрерсең анда үз хәлең, көләрсең, / Көләрлек булса, булмаса, йыларсың [Тукай, 1955, т. 1, б. 92].

Татар прозасында риваять сөйләүчеләрнең сүзе хикәяләнә торган кыйссаларда шарт фигыльнең кулланылышы. К. Насыйриның «Кырык вәзир» хикәятләрендә (1868): ...бер сүз сөйләсә олуғ қаза күрер. ...Әгәр син минем белән күңел бер итеп, бер күлмәктән башыңны чығарсаң wә минем сүземә илтифат қылып қарасаң, мин синең хафачалығыңны китәреп, хәтереңне шатландырырмын… [Насыйри, 1975, б. 221] һ.б. Аңлашылганча, К. Насыйри әсәрләрендә *-са* күрсәткечле шарт фигыль барлык затларга караган кушымчаларны алган хәлдә, төп фигыле хәзерге заман, киләчәк заман хикәя фигыльләре һәм боерык фигыль белән бирелә торган, ягъни шарт фигыль киләчәктә булачак реаль шартны белдерә торган җөмләләр дә актив файдаланыла.

К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда да (1881) шарт фигыльләрне куллану, нигездә, шушы тәртиптә бара: ...хәтеренә ниқадәр ғыйлемлек ала белсә, алыр. ...хаҗәт wақытта ут өстенә тотсалар, язуы заһир булыр. ...бу йегетнең бер генә һөнәрен безгә күрсәтсәң, булмасмы? Әгәр мағкул күрсәңез, хуш ула, бу тарафларға кәрам бойырасыз. Әгәр фәрманыңыз булса, баш өсте, бу хезмәтне әда қыйлайым [Насыйри, 1974, б. 212] һ.б. Күренгәнчә, «Әбүгалисина»да да «Кырык вәзир»дә дә шарт фигыльле җөмләләрнең күбесе, гадәттә, *әгәр* теркәгече белән башлана, бу үзенчәлек «Әнмүзәҗ»дә әдәби норма буларак искәртелә [Насыйри, 1975, б. 75].

К. Насыйри иҗатында төп фигыль *-а* яки *-р* күрсәткечле гадәти хәзерге заман хикәя фигыль белән бирелә торган, ягъни шарт фигыль гадәти, кабатлаулы реаль шартны белдерә торган җөмләләр дә файдаланыла: Малың булса, сиңа суғыш көнендә ғаскәр күп табылыр, қайда бал булса, анда чебен җыйыла. ...син бер кешенең нәфәкасен бирмичә, үзең алсаң, аның җанын алған кебек булырсың. Әгәр сиңа нәфәкасез ғаскәр кирәк булса, болар җитәр. һ.б. «Әбүгалисина» да: И шаһым, әгәр фәрман булса, бу йегетне йәнә Мисырға ирештермәк

бик асандыр. Әгәр дә шәфкатеңез булса, қайтырға мең җаным белән разыймән. Әгәр кәрәмеңездән илтифат бойырылса, ләззәтен белмәк мөмкиндер [Насыйри, 1974, б. 237]. Аңлашылганча, *-са* кушымчасы баш җөмләдәге фигыль белән вакыт мөнәсәбәтендә куела.

К. Насыйри иҗатында а) фаразый һәм ә) шактый сирәк булып, реаль булмаган шартны белдерә торган җөмләләр дә күзәтелә: а) «Кырык вәзир»дә: Әгәр патша, бу қадәр ақыл ийәсе вәзирләрен куйып, хатын сүзенә ийәрсә, қурқуым шулдыр ки, хақ тәғалә қаршында ғасыйлардан булмаса йарар иде [Насыйри, 1975, б. 237] һ.б. «Әбүгалисина»да: Әгәр дә бу мөшкилемезне ачсаң, ни гүзәл дәүләт wә биниһаят кәрамеңездән булыр иде [Насыйри, 1974, б. 244]. Җөмләләрдән күренгәнчә, фаразый шарт мәгънәсе *-са/-р иде, -са-ачак иде* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләрнең мөнәсәбәте белән белдерелә; ә) ирреаль шарт мәгънәсе *-кән булса/-р иде* күрсәткечле шарт-нәтиҗә фигыльләрнең мөнәсәбәте белән белдерелә: Әгәр анда һәлак иткән булсалар, минем сиңа ни файдам булыр иде. Без һәм фирақ уты белән мөбтәля булған булыр идек [Насыйри, 1974, б. 280] һ.б. Кире шарт модальлеге *булса да*, *исә дә* кебек формалар белән шарт фигыль формасына *-да* кисәкчәсе өстәлеп ясала: Бала булса да Әфләтүн хәким ди әйтергә йарар иде [Насыйри, 1974, б. 209]. Урта диалект сөйләшләрендә файдаланылганча [Юсупов, 2004, с. 524], гөман итү мәгънәсе белән *-са кирәк* тезмәсе кулланыла: Шайәть белсәм кирәк... [Насыйри, 1974, б. 252]; Мин шөйлә ғөман итәмен ки, бу эшләрне қыйлған адәм бөрадәрем Әбуғалисина булса кирәк [Насыйри, 1974, б. 263]. Күренгәнчә, әлеге мәгънә лексик чаралар белән дә ныгытыла.

*-са кирәк* тезмәсе I зат берлек һәм II зат күплек сан формасында, билгеле бер дәрәҗәдә ният кылуны, теләкне, эшләнергә тиешлекне дә аңлаткан хәлдә кулланыла: падишаһның қызын сорасам кирәктер. Ул заманда минем йәрдәмчем булырсың [Насыйри, 1974, б. 272]; ...Дәхи бик күп күзләр күрмәмеш, қолақлар ишетмәмеш һөнәр wә сәнғатьләр күрсәңез кирәк [Насыйри, 1974, б. 306]. Әлеге форма шушы ук типтагы җөмләләрдә *-ганда* формасы белән чиратлаштырыла, ягъни вакыт мөнәсәбәте тәгаенләнә: ...падишаһтан қыз сорағанда, миңа йәрдәм итәрсең [Насыйри, 1974, б. 273] һ.б. Шулай итеп, кыйссаларда *-са* күрсәткечле фигыльнең вакыт мөнәсәбәтен белдереп файдаланылуы аңлашыла. «Кырык вәзир»дә: ...һәркем аның җәмалына қараса, «ә фә сихрен һаза?» дийерләр иде, wә зифа буйына қараса, «ма һаза бәшарә?» дийерләр иде [Насыйри, 1975, б. 221]. Бу мәгънәләрдә *-са* һәм

*-гач* формалары берсе икенчесен алмаштырып та кулланыла: Малың булса, сиңа суғыш көнендә ғаскәр күп табылыр. ...қулымда мал булғач, мин күп адәм табармын [Насыйри, 1975, б. 226]. *-са* кушымчасының вакыт мөнәсәбәтен белдерү мәгънәсе «Әбүгалисина кыйссасы»нда да еш кабатлана: Чөнки суған суы белән йазғач, хажәт wақытта ут өстенә тотсалар, йазуы заһир булыр [Насыйри, 1974, б. 212]. Аңлашылганча, *-са* белән *-гач* кушымчаларының чиратлашуы бер үк форманы кабатлаудан коткара, әмма *-са* күрсәткече барыбер ешрак кабатлана.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы»нда (1887) *-са/-р иде* күрсәткечле шарт-нәтиҗә җөмлә мөнәсәбәте белән, реаль шартның гадәтилек мәгънәсе белдерелә: Һәр қайда бер доғасы қабул булған кешенен ишетсә wә қайда бер мөбәрәк урын бар диб хәбәр алса, анда барыб изге бала өчен доға wә мәдәд (ярдәм) эстәр иде [Фәизхан, 1896, б. 3].

*-са* боерык фигыль шарт-нәтиҗә мөнәсәбәте белән реаль шарт мәгънәсе белдерелә: ...әгәр дөньйаға бала килмәкне теләсәң, хәләл малыңдан мең ақча садақа бир... [Фәизхан, 1896, б. 3] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, тезмә әсәрләрендәге кебек үк, кыйссаи чәчмә әсәрләрдә дә шарт фигыльнең төрле ысуллар белән ясала торган реаль мәгънәсе ешрак кулланылуы күренә.

Татар прозасында авторның үз сүзен сөйләп хикәяләнә торган дәверен башлаган М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә шарт фигыльнең төрле мәгънә һәм формалары сурәтләү чарасы буларак файдаланыла. Бигрәк тә кире шарт модальлегенең, ягъни эшнең киресе булуын белдерә торган мәгънәнең эзлекле кулланылуы күзәтелә: ...Менла Хисаметдиннең мәрхүм атасы указный менла улмыш исә дә, уғылы атасының җәһәтенә муаффәқ уламады [Акъегет, 1886, б. 3]; ...Гәрчә бер хезмәтче тотса да wә чуқ дәфғә йаз wақыты иген эшендә башқа хезмәтчеләр йалласа да, әксәре үзе дә қара иген эшене эшләйүр иде [Акъегет, 1886, б. 4]. Мисаллардан аңлашылганча, кире шарт мәгънәсе *-мыш исә дә/-ды, -са да/-йур иде, -са дә/-сың кәрәк, -ды исә дә/-ды, -са дә/-р иде, -мыш исә дә, -ды исә* дә/хәзерге-киләчәк заман формаларының мөнәсәбәте белән белдерелә, билгеле бер шартлар үтәлмәгән очракта да, эшнең эшләнүен аңлата торган мәгънә әһәмиятле булып кала.

*-са* кушымчасының вакыт мөнәсәбәтен белдерүе «Хисаметдин менла»да да файдаланыла: Чөнки ғаwам йахшы белер ки, байны тәғзим итсәң, тупрағыны wә йирене иҗарәйә очсыз хақ илә алмақ мөмкин

[Акъегет, 1886, б. 12]; ...кәндем кәлмәсәм, бәнем эшемне кем эшләсен [Акъегет, 1886, б. 20] һ.б. Шулай итеп, *исә* ярдәмлеге белән ясалган тезмә һәм *-са да* формасы белән бирелә торган кире шарт фигыльләр һәм тагын *-ды исә (дә), -мыш исә (дә), -са дә, -р исә (дә)* кебек аналитик төзелмәләр дә киң кулланылыш ала.

З. Бигиевнең сәнгатьле прозасында да шарт фигыльләрне куллану, нигездә, шул тәртиптә бара, ягъни һәр өч зат кушымчасын алган хәлдә *-са* күрсәткечле фигыль, җөмләдәге төп фигыльнең нинди наклонение яки заманына мөнәсәбәтле рәвештә, төрле мәгънә төсмерләре белән кулланылышта була һәм тагын төрле аналитик төзелмәләр рәвешендә дә яши ала. Мәсәлән, «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә: Җәмғ улмыш җәмағать нумер эченә керергә нә қадәр қәсд итделәр исә дә, нумергә керүдән мәнгы қылындылар [Бигиев, 1991, б. 221]. Күренгәнчә, М. Акъегет әсәрендә актив булган *исә* ярдәмлеген бу әдип еш кына *улса* белән чиратлаштыра. З. Бигиев үзенең әсәрендә җанлы сөйләмгә хас булган *-ган булса да* тезмәсен дә куллана: Бер нәчә wақыт мөқаддәм Ғабденнәсыр әфәнде ...Хәдичә туташны йөз мең сум көмеш ақча илә кәләшлеккә алырға мәқсуды булған улса да, ...Хәдичә туташны вирмәмешләр [Бигиев, 1991, б. 226]. Әлеге форма «Гөнаһе кәбаир»дә дә файдаланыла: Кеше нә қадәр олуғ ғайеп wә җинайәть қылған булса да, һич дә әйтми мән бу эшдә гайепле дип [Бигиев, 1991, б. 268]. *-мыш исә дә* тезмәсе *-ган булса да* тезмәсе белән параллель кулланыла: ...гәрчә Муса әфәнде ул кичдә Габденнәсыр әфәнденең нумеренә бармаған булса да, [Бигиев, 1991, б. 232]; Маһруй ...нәҗат wә ғайебем йиңел улыр зан қылмыш исә дә... [Бигиев, 1991, б. 272]. *-ды исә* тезмәсе дә дәвам итеlә: Муса әфәнде мәхбүс улдисә, Хәдичә туташ wә йөз мең сум көмеш ақча Ғабденнәсыр әфәнденең улачақ [Бигиев, 1991, б. 226] һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, З. Бигиевнең сәнгатьле проза әсәрләрендә, М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында актив кулланыла торган *-ды исә, -мыш исә (дә)* формалы шарт фигыльләр дәвам ителгән хәлдә, җанлы сөйләмгә хас булган *-ган булса (да)* формасы белән дә чиратлаша башлый, әмма ләкин әлеге форма әдипнең «Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» юлъязмасында бөтенләй кулланылмый, фәкать *-мыш исә (дә)* тезмәле шарт фигыль генә файдаланыла: Тимерләң, тарихда золемлек илә наме шөһрәт булмыш исә дә, ғайәт ғақыйль, мөддәбир адәм иде [Бигиев, 1991, б. 293] һ.б.

З. Бигиевнең сәнгатьле проза әсәрләрендә *-са* кушымчасының вакыт мөнәсәбәтен белдерү мөмкинлеге, К. Насыйри, Ә. Уразаев-Кормаши, М. Акъегет әсәрләре белән чагыштырганда, шактый пассивлаша, киресенчә, әлеге вазифаны үтәү өчен, *-гач* кушымчасы ешрак кабатлана башлый.

Р. Фәхретдиннең һәр ике романында да шарт фигыльнең төп нигезен тәшкил итә торган *-са* кушымчалы формасы кулланылган хәлдә, тагын *-р исә (дә), -маз исә (дә), -мас исә (дә), -ды исә (дә), -макда исә (дә), -мыш исә (дә), -ып исә, -ачак исә, -ган улса (да)* кебек аналитик төзелмәләрдән дә киң файдаланыла. «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә, бигрәк тә, *-р исә (дә), -маз исә (дә)* формалары еш кабатлана: ...һәр сүзне аңламақ wә йәки фәзыл әһелләренең хөрмәтләрене йиренә кәлтермәк кеби бер Камаләт һәрбер кемсәнәдә табылыр исә дә, белгән илә белмәгән арасында һичбер айырма улмай, җөмлә адәм баласы бер тигез улмыш улыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267]; Тордығым мәдрәсәдә йәнәдән қырық йыл торыр исәм дә, сүз әйтәчәк йуқ иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268].

Аңлашылганча, *-р исә (дә), -маз исә (дә)* формалары, уңай шарт һәм кире шарт буларак, зат кушымчалары алган хәлдә кулланыла, кире шарт вазифасында, билгеле бер шартлар үтәлмәгәндә дә, эш яки хәлләрнең эшләнәчәге билгеле була.

Р. Фәхретдиннең әлеге әсәрендә *-р исә (дә), -маз исә (дә)* тезмәле шарт фигыльләр белән рәттән, сан ягыннан азрак булып, *-макда исә (дә)* формалы шарт фигыльләр дә кулланыла: Шәкертләремезнең мөназара wә бәхәс идешүләре мисалында һәркем сүзләмәкдә wә һәркем қычқырмақда исә дә, ишеткән wә дыңлаған бер кемсәнә йуқ иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 272]. Бу форма «Әсма, яки Гамәл вә җәза»да да бер мәртәбә кулланыла: ...сәламәтлегеннән мәмнүн улмақда исә дә, ...бәдбәхет улачағыны аңлап, қурықмаға башлады [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 349].

Аңлашылганча, *-макда исә дә* тезмәле шарт фигыль фәкать кире шарт мәгънәсе белән генә файдаланыла.

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» романында берәр мәртәбә *-ып исә, -ачак исә* формалары кулланыла: Пароходта халық шул қадәр күп иде ки, инә ташланыб исә йиргә дөшмәз дигән сүз, бу урынға туғры кәлмәкдә иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 272]; – Бер шарт илә иде. – Нә кеби шарт? – Зат ғалийәңезнең морады wә рәхәте шу йулда улачақ исә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 308].

Әлеге җөмләләрдәге *-ып исә, -ачак исә* формалары, асылда, икесе ике төрле мәгънә аңлата: *-ып исә* формасы, *-маз* кушымчалы фигыль белән бергә гадәти-даими, *-ачак исә,* киресенчә, бер мәртәбә көтелә торган мәгънәне белдерә. «Әсма, яки Гамәл вә җәза»да бер мәртәбә *-ачак исә дә* формасы файдаланылган: һәр нәқадәр мәғлүм хадимә асраулық урыны табып бирәчәк исә дә, йәшь қызның башыннан күп нәрсәләр үттегеннән, күңеле һәр шәйдән қурқыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 349].

Р. Фәхретдиннең әлеге әсәрендә *-ды исә (дә)* формалы шарт фигыль дә күзәтелә: һәр нә қадәр йазар wә уқырға белдең исә дә, бу қадәр илә генә атаң Камаләтенә варис ула алмазсән [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267]. Әлеге форма әдипнең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә киң кулланылыш ала: Габбас менла яшьлегендә ...бер бала иде исә дә, ...имам булды [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 312]; .. өмид идеп торды исә дә, ...әүwәлгедән артық тәкәбберлелек, хөсет, ходбинлек ийәртеп килде. ...берқадәр хезмәт итде исә дә, ...қайтып китде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 316].

Менә шул рәвешле, *-ды исә дә* формасы рәттән тезелеп бара. Татар әдәби теленең озын тарихлы дәверендә һәм татар сөйләшләренең кайберләрендә актив булган [Рамазанова, 1992, б. 32] *-ды исә* формалы шарт фигыль Р. Фәхретдиннең бу романында фәкать кире шарт мәгънәсе белән генә файдаланыла.

«Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә «Сәлимә, яки Гыйффәт»тә еш кабатлана торган *-р исә (дә), -маз исә (дә), -мас исә (дә)* формалары да күзәтелә: Йосыф бабайда бер гүзәл холык бар иде ки, боңар ишарәт итмәй китәр исәк, бер кемсәнең бер Камаләтене яшермеш улачагымыз шөбһәсездер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 325]. Әсманы һәр нәқадәр Ғаббас мелла дәрәҗәсендә улмаз исә дә һәмишә гүзәл тәрбийә итмәкдә улды [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 324]. Күренгәнчә, *-маз* һәм *-мас* формалары чиратлаша, баш җөмләдәге төп фигыльгә бәйле рәвештә, сөйләү моментында актуаль булган һәм гадәти, даими хәлләрне аңлата.

Р. Фәхретдиннең һәр ике әсәрендә, югарыда каралып үткән аналитик шарт фигыльләргә караганда, сирәгрәк булып, *-мыш исә (дә)* формасы да файдаланыла: Гәрчә дәрес алдығым ислам ғыйлемләреннән, дәрес фәннәреннән бер қадәр хәбәрем улмыш исә дә, бунда һәм Сәлимә туташқа тиңдәш дәгел идем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 296]. Бу форма *-ган улса иде* тезмәсе белән чиратлаша: Кашки ошбу

сәғатьләрдән беразларыны ғыйльме тарих, ғыйльме нәсәб кеби нәрсәләр илә шөғельләнгән улсам иде, ошбу көндә бер қыз хозурында мәлзәм (оядлы) улып қалмаз идем. Әгәр дә белгән улсам иде, бәннән ашарға сорамаз, бәлки ашарға виргән булыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 296]. Аңлашылганча, соңгы җөмләләр авторның үз исеменнән аның тормышка ашмаган хыялында гына булып калган теләген чагылдыра, димәк әлеге җөмләләр шартлы теләкне белдерә була. Сүз җаенда әйтеп үтәргә кирәк, бу автор *-са иде* формасы белән өмет ителгән теләкне дә аңлата: Шулай исә дә, шатлық хәбәрләрене ишетмәк мөйәссәр улса иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 309]; Әман йарабби, хәйерле улса иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 345] һ.б.

Р. Фәхретдиннең сәнгатьле проза әсәрләреннән аермалы буларак, Ф. Кәриминең хикәяләрендә аналитик төзелмәле шарт фигыльләрне куллану шактый сирәгәя, уңай шартны белдергәндә синтетик *-са* кушымчасы, кире шартны белдергәндә *-са да* күрсәткече активлаша. Мәсәлән, «Салих бабайның өйләнүе»ендә: Сөйләсәм, берне генә сөйлим инде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 221]; һәр мәртәбәсендә шулай әйтсә дә, икенче мәртәбәсендә тагын хикәйәт таба торған иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 221] һ.б. Күренгәнчә, эзлекле булып, *-са* һәм *-са да* формасы бара, кире шартны белдерә торган җөмләләр еш кабатлана. Әдипнең башка әсәрләрендә дә шушы тәртип дәвам итеЛә, *исә* ярдәмлеге пассивлашу белән бергә, *улса* ярдәмлеге дә җанлы сөйләмә рәвешен ала: «Салих бабай»да: Ничек булса да, бу қызларның йанына барып, азрақ сөйләшмәкче булдым [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 226]. «Җиһангир мәхдүм»дә: Матчасы дәхи бик черек булса да, ике җирдән бағана берлә терәтеп куйылған иде. Мәктәпнең дүрт тәрәзәсе булса да, күбесенең пыйаласы wатылған иде. [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 231]. «Бер шәкерт илә бер студент» хикәясендә: Шуның җирендә сез булсағыз, ни эшләр идегез [Кәрими, 1996, б. 31]. «Морза кызы Фатыйма»да: Мәғлүмдер ки, бай кешенең қызы булса, аның җиткәнене көтеп кенә торалар. ...Әгәр байның қызы матур да булса, ул wақыт аның шөһрәте күккә чығадыр [Кәрими, 1996, б. 88]. Әйтелеп үтелгәнчә, бу әдипнең сәнгатьле проза әсәрләрендә, аналитик формалы шарт фигыльгә караганда, *-са* кушымчасы белән белдерелә торганнары активрак, алар төп фигыльнең заман һәм наклонениесенә мөнәсәбәтле рәвештә, төрле мәгънә төсмерләре белән файдаланыла.

Ф. Кәриминең матур әдәбият әсәрләренең текстларында аналитик формалы традицион шарт фигыльләр, гадәттә, персонаж сөйләмендә,

яисә уртак сөйләмдә кулланыла. Мәсәлән, «Җиһангир мәхдүм»дә: Бинаән ғаләйһи атна кич малайлар мендәрле уйнағанда wә йәки мужик кергән чақта, аны мендәр илә қыйнап чығарғанда, шул бағаналарға бик қаты килеп бәрелмәс исәләр, түбә тақтасының ишелеп төшмәк ихтималы йуқ иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 231]. «Бер шәкерт илә бер студент»та: ...тиз бер заманда мөселманча wә русча уқуның кирәк булдығыннан сүз ачылса: «Бабаларыбыз заманында ничек булған исә, безгә дә шулай торырға кирәк. Башка төрлесе бидғатьдер» – дип, қара халықны аздыра торған кешеләребез бик күп… [Кәрими, 1996, б. 48]. «Морза кызы Фатыйма»да: – Ничек мәэйүс уласың? Бәңа сахиб wә рәфиқ улыр исәң, кәндеңе талиғсыз ғад итмәссең зан итәрем [Кәрими, 1996, б. 96] һ.б.

Ф. Кәриминең сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә *-са* кушымчасы чагылыш тапкан *алай булса, шулай булса, ничек булса* кебек төзелмәләр еш кабатлана. «Җиһангир мәхдүм»дә: Хәзрәт бик һиммәтле, бик тәқwа кеше, ничек булса да шул мәдрәсә қайғысыны бер дә хәтердән чығармыйдыр [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 240]. «Бер шәкерт илә бер студент»та: Ничек булса да бу хәзрәт белән танышып, бер сохбәт итәсем килде [Кәрими, 1996, б. 32]. «Нуретдин хәлфә»дә: Ләкин шулай булса да садақа wә фитраларыңыз илә зәкуәт wә ғошерләреңезне безгә биреңез [Кәрими, 1996, б. 62]. «Морза кызы Фатыйма»да: Фатыймаға бәнем букет күндермәклегем, ничек булса да, килешеп бетмәс [Кәрими, 1996, б. 86] һ.б.

Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә *-са* күрсәткечле фигыльләрнең, сәнгатьле проза әсәрләре белән чагыштырганда, сан ягыннан азрак булуы игътибарны җәлеп итә, булганнары да *-р исә, -йур исә (дә), -мас исә (дә), -ды исә (дә), -мыш исә (дә), -ачак исә, -ачак булыр исә (дә)* формалы аналитик төзелмәләрдә кулланыла. Мәсәлән, «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә: ...бу қадәр хәзерлек бик аз кеби күренер исә дә, ...хәтта бераз чуқ та булмыш [Кәрими, 1996, б. 151]. «Кырымга сәяхәт» юлъязмасында *-ачак исә* формасы да кулланыла: Әгәр сез чықмайачақ исәңез, лотфән, бәнем әшьйамны да бақмаңызны рижа итәрем [Кәрими, 1996, б. 322]. Шул ук вакытта *-ачак булыр исә* формасының кулланылуы да дәвам итеЛә: ...никях wақытында, хатын ире булачақ адәмгә: «Бәне ғайре мәшрүғ сурәтдә сүксәң, йахуд орсаң, бәңа ризық wә нәфәқа қалдырмадан фәлән қадәр көнлек сәфәргә китәрсәң, бәне кәнде туғдығым wә йөрдегем йирдән башка тарафларға алып китәчәк булырсаң, бәнем үзәремдән икенче хатын алыр булырсаң, исереклек

wә йалкъаулык итеп ғаиләне тәрбийә итмәйәчәк булдырсаң, сәндән айырылмаға ихтыйарым кәнде әлемдә булачакдыр» – дийә бер, йахуд берничә шартлар илә никяхланачак булыр исә, шәриғать исламийа боңа тәмамилә мөсағадә wә рөхсәт бирәйүр [Кәрими, 1996, б. 329] һ.б.

Ф. Кәриминең хикәяләрендәге *булса* ярдәмлеге урынында, сәяхәтнамәләрендә исә *ничек булса да* төзелмәсе урынына *нәсыл исә* формасы файдаланыла: Мулламы дийәлем, мужикмы дийәлем, хасыйле, михрабка кереп имамәт итмәк өчен указ алған бер адәм, насыл исә дә, раст килеп, бер wакыт әленә җәридә алыр [Кәрими, 1996, б. 181]; Нәсыл исә дә, без моңа диккать итмәмешмез [Кәрими, 1996, б. 187] һ.б.

Шулай итеп, Ф. Кәриминең матур әдәбиятка караган әсәрләренең текстларында һәм сәяхәтнамәләрендә кулланылган *-са* күрсәткечле шарт фигыль, бигрәк тә аның тезмә формалары, махсус сайланып алына, функциональ-стилистик вариантлылык хасил итә дип әйтә алабыз.

Татар прозасында образлап хикәяләүне башлый торган классик әдипләрнең беренче әсәрләрендә үк татар әдәби теленең җәдиди госманлы варианты белән языла торган текстларда эзлекле булып кулланыла торган аналитик формалар шактый сирәгәя, шуңа күрә, беренчедән, *-са* кушымчалы шарт фигыльнең мәгънәсе *исә* ярдәмлеге алдыннан килә торган фигыль формасының мәгънәсенә нигезләнә алмый, иярчен кушма җөмләнең баш җөмләсендә килә торган төп фигыльнең заман һәм наклонениесенә ныграк бәйләнә һәм аларның мөнәсәбәте катлаулана, хәзерге әдәби телдә норма буларак карала торган мәгънә төсмерләре барлыкка килә; икенчедән, *-са* кушымчасы чагылыш тапкан һәм җанлы сөйләмдә актив яшәештә булып ныгыган төзелмәләр ешрак кабатлана; өченчедән, кире шартны белдерә торган *-са да* һәм шартлы теләкне аңлата торган *-са, -р иде, -ачак иде* формалары киңрәк кулланыла; дүртенчедән, әлеге мөмкинлектән һәр автор һәр әсәренең эчтәлегенә, образлар системасына кирәк булган дәрәҗәдә генә файдалана, сайлап ала, димәк, тасвирлау чарасына әверелдерә.

*Кыскача нәтиҗәләр.* XIX гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән тезмә һәм чәчмә әсәрләрдә шарт фигыль, асылда, *-са, -са да, -са ирде, -са кирәк, улса, -р булса, -са исә дә* формалары белән кулланылса, автор үз сүзен сөйләп хикәяләнә торган әсәрләрдә уңай һәм кире шарт мәгънәсен белдерә торган формаларның саны күпкә арта. Реаль, фаразый, ирреаль, кире шарт мәгънәләренең белдерелүен аңлау өчен, нәтиҗә җөмләнең фигыль күрсәткечләре белән булган мөнәсәбәтне синтетик *-са* кушымчасының күп сандагы аналитик формалары *-са,*

*-са да, -са иде, -ды исә (дә), -мыш исә (дә), -ган исә (дә), -р исә(дә), -йур исә (дә), -маз исә (дә), -мас исә (дә), -макда исә (дә), -ачак исә (дә), -ып исә, -са кирәк* кебек аналитик тезмәләр белән бергә карарга кирәк була. Аңлашылганча, аналитик шарт фигыльләр угыз һәм кыпчак телләренә хас булган ике әдәби тел нормасында кулланыла, аны графо-орфографик һәм морфологик вариантлылык дип карарга мөмкин була. *-са* кушымчасы сакланган хәлдә, әлеге тезмәләр төрле авторның төрле жанр-стильдә язылган текстларында һәрберсендә төрле ешлыкта кабатланып кулланыла, димәк, функциональ-стилистик вариантлылык та хасил итә.

Әлеге үзенчәлек классик әдипләр иҗатында да дәвам итеlә, ягъни татар әдәби теленең җәдиди госманлы варианты белән языла торган текстларда эзлекле булып кулланыла торган аналитик формалы шарт фигыльләрен файдалану сирәгәя, шарт фигыль белән нәтиҗә җөмләдә килә торган фигыльнең заманы һәм наклонениесе мөнәсәбәте белән белдерелә торган мәгънә, хәзерге әдәби телдә норма буларак карала торган мәгънәләргә якыная һәм, берничә форманың бергә генә калуы сәбәпле, катлаулана; *-са к*ушымчасы чагылыш тапкан һәм җанлы сөйләмдә актив яшәештә булып ныгыган төзелмәләр ешрак кабатлана, шартлы теләкне белдерә торган фигыль формалары активлаша, боларның барысы да һәр авторның һәр әсәренә кирәк дәрәҗәдә сайланып алына, образ барлыкка китерү чарасы буларак күтәрелә.

*Шартлы теләк фигыль.* Хәзерге татар әдәби телендә, сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерә торган модальлек функциональ-семантик категориянең бер күрсәткече булган шартлы теләк (конъюнктив) наклонениесе *-р иде* (төп форма), *-ган булыр иде, -ачак иде, -а иде* кушымчалары ала дип белдерелә [Юлдашев, 1965, с. 247–261]. Шул ук вакытта *-р иде, -а иде* формалары үткән заман хикәя фигыль формалары дип тә карала [Юлдашев, 1965, с. 128, 251]. Шартлы теләк фигыльнең мәгънәсе «Татар грамматикасы»нда тәфсилләп аңлатыла: «Димәк, шартлы теләк наклонениесе, сөйләүче тарафыннан фараз ителгән һәм контекстта теләк, өндәү, үкенү экспрессив-эмоциональ мәгънәләр алган эш-хәлләрне белдерә. Шул рәвешчә, бу наклонение фаразый һәм ирреаль (реаль булмаган) шарт-нәтиҗә җөмләләрдән аерылып чыккан булырга тиеш. ...Шартлы теләк фигыль мәгънәсе *-ган булыр иде* формасы белән генә түгел, *-ачак иде* формасы белән дә белдерелә ала. *-а иде* формасы исә шартлы теләк фигыль мәгънәсендә сирәк кулланыла...» [Татар грамматикасы, 2002,

б. 165]. *-ачак иде* һәм *-р иде* формалары шартлы теләк мәгънәсен дә, хикәя фигыль мәгънәләрен дә белдерүе белән бергә, *-р иде* формасының хикәя фигыль мәгънәсен югалта баруы, төп функциясе шартлы теләк наклонениесен белдерүгә кала баруы, *-ачак иде* формасы хикәя фигыльнең үткән-киләчәк заманын белдерүдә бердәнбер форма булып калуы ассызыклана. Шартлы теләк фигыль мәгънәсенең тагын *-гый(ы), -асы иде, -сын иде, -рга иде* формалары белән дә белдерелә алуы ассызыклана [Татар грамматикасы, 2002, б. 167].

Татар теленең диалект һәм сөйләшләрендә шартлы теләк наклонениесе әдәби телдәге мәгънәләре белән аналитик *-ыр иде, -а иде, -асы иде, -ачак иде, -ды иде, -ган булыр иде, -мак ите* формаларда чагылыш таба дип күрсәтелә [Юсупов, 1986, с. 261–264; 2004, б. 527–531].

Әлеге мәгълүматларны истә тоткан хәлдә, XIX гасыр – XX йөз башында төрле жанр-стильдә язылган текстларда *-р иде* формасының, хәзерге әдәби телдәге кебек, билгесез киләчәк заманны гына түгел, *-а иде* формасы кебек тәмамланмаган үткән заман формасының мәгънәсе белән дә төрле ешлыкта кабатланып, төрле дәрәҗәдә кулланылыш табуы билгеле булганга, бу үзенчәлекне аерып карарга кирәк булачак.

Хикәя фигыльнең аналитик формалары турында сөйли башлаганда, әйтелеп үтелгәнчә, күрсәтелгән чорда язылган татар теле грамматикаларында әлеге формаларга төрле хезмәттә төрлечә аңлатма бирелә. Г. Фәезханов үзенең «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» (1887) хезмәтендә *иде* ярдәмлеге белән ясала торган фигыльләрне хикәя фигыль дип атый: «*...-а иде* формасы мөсбат фигъле хәл, ягъни исбатланган хәзерге, *-р иде* формасы мөсбат фигъле мозаригъ, ягъни исбатланган, дөреслеге дәлилләнгән киләчәк, *-асы иде* формасы мөсбат фигъле мәстәкъбәл, ягъни исбатланган киләчәк...» дип аңлатыла, әлеге формаларның берлек һәм күплек санда һәм III затта да төрләнеш үрнәкләре күрсәтелә [Фәизхан, 1887, б. 30]. К. Насыйриның «Әнмүзәҗ»ендә (1895) *-р иде* формасы «җөзъәи шарт», ягъни шартның бер өлеше, аңа бәйле булган фигыль дип аңлатыла, *-са иде* формасын «сыйгаи тәмәнни», ягъни теләү, өмет итү, ялвару фигыле дип атый [Насыйри, 1975, б. 75]. *-а иде* формасы хакында фикер әйтелми. М. Өметбаевның «Татар нәхүсенең мохтәсары» (1901) дәреслегендә, *-а иде* формасы «мазый мәҗһул», ягъни үткән билгесез, *-р иде* формасы «мазый чәнбәр», ягъни берникадәр элек үткән ... заман дип бирелә [Өметбаев, 1901, б. 26–27].

Шулай итеп, татар телен фән буларак өйрәнеп язылган беренче хезмәтләрдә *иде* ярдәмлеге белән ясалган формаларның, нигездә, хикәя фигыльгә каратылуы күренә, шул ук вакытта *-са иде* формасының теләкне, *-р иде* формасының шартны белдерә торган эш-хәлләргә бәйле булуы да искәртелеп үтелә. Димәк, бу формаларның нинди мәгънә белдерүләре, билгеле бер дәрәҗәдә XIX гасыр башында ук ачыкланган [Гиганов, 1801, с. 94], шуңа карамастан, XX гасырның 60 нчы ел ахырларына кадәр *-р иде (булыр иде)* формасы теләк фигыль дип аңлатылып килә [Хангильдин, 1954, б. 246].

Хәзерге тел белемендә *-р иде, -а иде* формалары һәм үткән заман хикәя фигыль, һәм шартлы теләкне белдерә торган фигыль дип өйрәнелә [Тумашева, 1986, б. 42, 61, 133–134; Юсупов, 1986, с. 142, 160, 261–262], *-са иде* формасының теләкне белдерүе ассызыклана [Тумашева, 1986, б. 118].

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле белән язылган сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә *-р иде* формасының шартлы теләкне белдереп кулланылуы, асылда, барлык текстларда да күзәтелә, әмма аның ешлыгы хикәяләү ысулына бәйле була. Кеше сүзен сөйләп хикәяләнә торган К. Насыйри кыйссаларында да, үз сүзен сөйләп хикәяләнә торган мәгърифәтче әдипләр иҗатында да *-р иде* формалы фигыльнең шартлы теләкне белдерү мәгънәсе белән файдаланылуы, классиклар иҗаты белән чагыштырганда, сан ягыннан азрак икәнлеге күренә.

К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда *-р иде* формасының шартлы теләкне белдерә торган мәгънәсе белән кулланылуы, «Кырык вәзир» хикәятләренә караганда, ешрак кабатлана, түбәндәге җөмләләрдә чагылыш таба: Ул исә хәлвә ашамақ түгел, мөмкин булса, Әбүғалисинаның қанын эчәр иде [Насыйри, 1974, б. 262]; Қызны бирмәк түгел, қодрәтеннән килсә, тереләй тотып ашар иде [Насыйри, 1974, б. 262] һ.б. Мисаллардан аңлашылганча, әлеге җөмләләрдәге шартлы теләк III затка нисбәтле рәвештә бирелә. II затка караган шартлы теләк белдерелгән вакытта иярчен җөмләнең хәбәре үтенү мәгънәсендәге хикәя фигыльнең II зат күплек саны белән бирелә: И ғазизем wә миһербан кунағым, хуш ула, минем кибетемә рәхим итәсез, мәҗлесеңез белән мөшәррәф булыр идек. Сез дәхи атамыз урынына ата булыр идеңез [Насыйри, 1974, б. 227].

Бу позициядә, ягъни шарт фигыль II затта булганда, баш җөмләнең хәбәре булып *-са иде* формалы фигыль дә килә ала: ...кәрәм итсәңез, хәммам зийафәте миннән булса иде, диде [Насыйри, 1974,

б. 224]. III затка күчерелгәндә, шул ук мәгънә *-са* формасы белән бирелә: Ғаҗәбә, бу мәртәбә мөмкин булмыйдырмы, атамнан мине сезнең өчен, Аллаһе тәгаләнең әмере белән, шәриғате мөхәммәдийә үзрә хәләл җефетлеккә сораса? Атам йуқ димәс, бәлки разый булыр иде. [Насыйри, 1974, б. 247]. Мисаллардан аңлашылганча, бу төр *(-са, -р иде, -са иде)* барлык җөмләләрдә үзара сөйләшкән, аралашкан вакытта кулланыла, персонажларның үз арасындагы мөнәсәбәте: ниндидер шартларның үтәлү-үтәлмәвенә бәйле булган теләге, шуның тормышка ашуын күрергә омтылуы чагыла. Үкенү төсмере белән әйтелә торган тиешлекне аңлатканда шарт фигыль I зат күплек формасында куела: Бирсәк, бу қадәр һәлакәтләрне күрмәс борын бирер идек [Насыйри, 1974, б. 285]. Хәзерге әдәби телдә әлеге җөмләне: «Бирсәк, бу кадәр һәлакәтләрне күрмәс борын бирергә иде (бирәсе иде)» формасында әйтергә мөмкин.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында да шартлы теләкне белдерә торган җөмләләр еш кабатлана дип әйтеп булмый, түбәндәге мисалларны күрсәтергә мөмкин: Йуқса хәлифәләр ислам шәриғатенчә торсалар иде, мәзкүр дәүләт хәзер дә мәүҗүд ула белер иде, – диде Хисаметдин [Акъегет, 1886, б. 24]; – Йуқ дуслар, бәнем ақчам күп булса иде, адымны онытмазлар иде... – диде Мохтар [Акъегет, 1886, б. 32].

Мисаллардан күренгәнчә, әлеге әсәрдә шартлы теләкне белдерә торган мәгънә *-са иде, -р иде* формасында төзелә, *-са иде* күрсәткече фаразый-хыялый теләкне белдерә, шуңа күрә *-р иде* формасы да әлеге гөман итүле теләкнең үткәнгә караганлыгын аңлата [Юлдашев, 1965, с. 258]. III затка мөнәсәбәтле булган төп җөмләләрдә *-са иде* формасы *-ган булса иде* тезмәсе белән дә алмаштырыла ала: Йуқса хәлифәләр ислам шәригатеңчә торган булсалар иде, мәзкүр дәүләт хәзер дә мәүҗүд ула белер иде, – диде Хисаметдин. Шулай итеп, хыялый теләкне белдерү мәгънәсе үткәндә булган шартларга бәйле хәлдәге ышанычлы гөман итү белән алмашына.

Иң мөһиме, әлеге әсәрдә *-р иде* формалы җөмләнең мөстәкыйль рәвештә кулланылуы күзәтелә: Ләкин бән сәндән дә тиз қайтыр идем – сүзене вирмәде Зурқолақов [Акъегет, 1886, б. 65]. *-р иде* формалы җөмләнең мөстәкыйль рәвештә кулланыла алуын галимнәр рус теле йогынтысы дип санау ягында торалар [Юлдашев, 1965, с. 253].

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә татар прозасын хикәяләүдә уртак сөйләм күренеше бирелә башлый һәм ул шартлы

теләкне белдерә торган җөмләдә чагылыш таба: Йуқ, туйдан аның хәбәре улмаса кәрәк, улса иде, бақчаға, әлбәттә, җитешер иде. Һай кош улса идем, очып йаныңа җитешеп, хәлемне сәңа белдерер идем [Акъегет, 1886, б. 55].

Шулай итеп, шартлы теләкне аңлата торган җөмләләрнең барысы да диярлек персонажларның үзара мөнәсәбәтен тасвир иткәндә кулланылуы мәгълүм була. Әлеге үзенчәлек З. Бигиев әсәрләреңдә дә дәвам итеlә. Мәсәлән, «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәреңдә: Хадимәнең җаwабы бу тарыйқа тәмам булғач, тәфтишчеләр ишек йанына кәлеп қарасалар, ишектә йозақны ачқычы илә күреп, тәфтишчеләр тәғаҗҗебләнеп: ...әгәр дә ишекне йозақ илә бикләп китсә иде, бу хатынның үлтерелдегене белү кәчегеп, қатыйльгә гизләнергә дә форсат булыр иде... – диделәр [Бигиев, 1991, б. 222]; Мәктүбемдә: бәңә кәләш улырға разый улсаңыз, бән сезне хатынлықға алыр идем, дәйү йазған идем [Бигиев, 1991, б. 230] һ.б.

Китерелгән мисаллардан аңлашылганча, З. Бигиевнең әлеге әсәрендә җөмләләр шактый катлаулы төзелсә дә, шартлы теләк мәгънәсен алып килә торган нигез, гадәттә, бер типта *-са иде, -р иде* формасы белән бирелә. Бу әсәрдә дә *-р иде* формалы җөмләләрнең мөстәкыйль рәвештә кулланылуы күзәтелә.

Әдипнең «Гөнаһе кәбаир» романында да әлеге фигыль шул ук тәртиптә кулланыла: ...Маһруй бөйләчә сүзә дәwам итте: – Әгәр дә сән қабул итсәң, мән баланы сәнең өйеңдә қалдырыр идем. Сән йахшы ғына тәрбийә қылыр идең. Мән үзем дә форсат wақытларда кәлеп қарар идем. [Бигиев, 1991, б. 263]; Әгәр дә мәнем өйемдә бала туғдырымыш улса идең, мән ул эшне бер дә сәтер қыйлмайынча, хөкем хозурына әйтер идем [Бигиев, 1991, б. 270]. Күренгәнчә, җөмләләр *-са, -са иде, -р иде* мөнәсәбәтендә төзелә. Бу төрдәге җөмләләрдә *-са* һәм *-са иде* формалары берсе икенчесенең дублеты булып карала ала [Юлдашев, 1965, с. 234].

Шартлы теләкне белдерә торган җөмләләр Ф. Кәрими әсәрләрендә ешрак кабатлана башлый. Бу типтагы җөмләләрнең төзелешендә традицион нигез саклана: ...әгәр дә син дә wәғдә биреп, сүзеңдә торсаң, йаңадан җан бағышлап, мине тергезү дәрәҗәсендә сөйендерер идең, – дидем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 228]; Мосье Пасторның шәкертләреннән бер бактериолог күрмеш улса иде, ...мондайын җиргә мәктәп салырға, йахуд мәктәп йанына тирес түгәргә йарамадығыны аңлатыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 231].

Урыны-урыны белән бу тип җөмләләр күләм ягыннан киңәя, ягъни бер баш җөмләгә караган берничә иярчен җөмлә бирелә: ...аннан соң кәнә үз телемездә қысқача wә ачықча итеп, иқтиқад wә ғамәл мәсьәләләрен үгрәтсәләр, берқадәр әхлақ wә әдәп-тәрбийә белдерсәләр wә һәр кеше өчен бөтен ғомере буйынча лазем булған ғыйльме хисаптан, wә гәрчә бәк қысқа булса да, қыйссас әнбийә, тарих wә җәғрәфийәдән хәбәр wә мәғлүмат бирсәләр wә андан соң қулыннан килгән кешегә балаларын рус мәктәпләренә җибәреп, русча уқырға wә берәр төрле һөнәр wә сәнәғатькә үгрәнергә қушсалар, мужикларымыз – һәм халис мөселман, һәм дә үзләренә wә кешегә файда китерә торған берәр адәм булып ғомер кичерерләр wә киткән сайын мәғыйшәтләре төзәлер иде [Кәрими, 1996, б. 73] һ.б. Күренгәнчә, шартлы теләкне алып килә торган җөмләләр *-са, -са иде, -р иде* формалары белән төзелә, билгеле бер шартлар үтәлгәндә тормышка ашачак теләк белдерелә.

Шуның белән бергә, Ф. Кәрими әсәрләрендә, гөман итүнең үткәнгә каратылганын белдерүче *-са, -ган булыр иде* формалары белән төзелә торган җөмләләр дә кулланылу активлаша: Ихтимал ки, без булмасақ, болар чегәннәрдән қурыққан да булырлар иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 225]; Әгәр морза Туғанский, ...кибарлық wә олуғлықның морза булуда түгел, бәлки күңел тынычлығында икәнлеген белмеш булса иде, Мостафа кеби вөжданлы wә инсанийәтле бер йегетне бер дә хур күрмәйенчә, ике мәғсум қалебне берләштерәрәк, аларны бәхтийәр wә мәсғуд итеп, кәндесен дә бу кеби кәбәр wә хәсрәтләрдән wә дуст-дошман арасында мәсхәрә булудан қотқарған булыр иде [Кәрими, 1996, б. 113–114] һ.б.

Ф. Кәриминең сәнгатьле прозасында фәкать бер-ике урында *-са, -ачак иде* формалары белән төзелгән шартлы теләкне белдерә торган җөмләләр күзәтелә: Сезнең ихтыйарыңызға тәслим улынсам, бәне шул Ғабдегәрәйгә вирәчәк түгелме идеңез [Кәрими, 1996, б. 116]; Әгәр сүз башларға депутатқа қалса, эш мөшкел булып, ни димәгә дә белмәйәчәк иде [Кәрими, 1996, б. 124]. Аңлашылганча, үткәнгә каратылган гөман итү тиешлек төсмере белән әйтелә.

Ф. Кәриминең хикәяләрендә бер-ике урында гына күренеп киткән бу ысул Р. Фәхретдин әсәрендә шактый активлаша. Мәсәлән, Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» романында: Кашки аңладығым қадәр фарсычаны сүзләргә wә җаwап вирергә белсәм иде, үземнең урыным дәгел, бөтен пароходы бәнем улса иде, һич шөбһәсез

фида идәчәк идем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 275]; ...Заманымызның әдәп wә мәғаширәте йәки модасы нә улса да улсын, бән мода әсире дәгел идем. Изгелек нә йирдә улса, бәнем қашымда мода шу улачақ иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 275].

Үзеннән-үзе аңлашылганча, Р. Фәхретдиннең әлеге әсәрендә, шартлы теләкне белдерә торган җөмләләрдә, аңа кадәр язылган әсәрләрдәге кебек үк, баш һәм иярчен җөмләләрнең үзара бәйләнеше *-са, -са иде, -р иде* формалары белән дә башкарыла торган мисаллар да кулланыла: Әгәр дә әүwәлдән белешкән улсақ иде, бу кеби йаңлыш зан илә йөрмәк шуйлә торсын, бәлки бер-беремезгә йәрдәм идешкән улыр идек [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 279]; Әгәр дә белгеч улсам иде, бәннән ашарға сорамаз, бәлки ашарға виргән булыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 296] һ.б.

Шарт фигыль турында язганда, Р. Фәхретдин әсәрләрендә *исә* ярдәмлеге белән ясалган төрле аналитик төзелмәләрнең файдаланылуы хакында әйтелде, аларның күбесе кире шартны барлыкка китерүдә катнашканга булса кирәк, шартлы теләкне белдерә торган җөмләләрдә шактый сирәк кулланылалар: Һәр сүзне аңламақ wә йәки фәзыл әһелләренең хөрмәтләрене йиренә кәлтермәк кеби бер Камаләт һәрбер кемсәнәдә табылыр исә, белгән илә белмәгән арасында һичбер айырма улмай, жөмлә адәм баласы бер тигез улмыш улыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 267]; Әгәр дә капитанға хәлләрене белдерерләр исәләр, әлбәттә, урын булыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 283].

Р. Фәхретдиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) романында да шартлы теләкне белдерә торган иярчен кушма җөмләләрнең хәбәрләре, асылда, шул ук *-р исә,* яисә башка аналитик төзелмәләр белән бирелгән хәлдә кулланыла: Ғаббас мелла, әгәр дә кәндесе кеби җиңел фикерле, дөньйаға илтифатсыз бер хатынға туғыры килмеш улса да, ғомерене ахмақлар ғадәте үзрә сәфаһәт дөньйаларында кичермәк wә бөтен фамилийәсенең шәрафәтенә дегет буйап, дөньйасына вәдағ идәчәк иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 312]; Ләкин әгәр дә «ысулы җәдидә» дийә зикер итмеш улса да, мәхәллә тарафындан кинә сүз улачақ дәгел иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 313] һ.б.

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, шартлы теләкне белдерә торган җөмләләр, нигездә, бер стандарт белән төзелә: *әгәр* дип башлана, шартны белдерү *-са иде, -р исә* формалары белән бирелә, баш җөмләнең хәбәре *-ачак иде, -р иде* күрсәткечле фигыль була.

Ф. Кәриминең дә, Р. Фәхретдиннең дә фәнни хезмәтләрендә һәм публицистик мәкаләләрендә шартлы теләкне белдерә торган җөмләләр бөтенләй кулланылмый диярлек. Ф. Кәриминең юлъязмаларында диалоглар бирелгән вакытта гына шартлы теләк фигыльләре күзәтелә. Мәсәлән, «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә: ...мәктәбеңездәге укулар бераз низам wә тәртип илә улырса wә шәкертләрдә дәһа зийадә истифадә идәрләрсә, дәһа муафиқ улыр иде дийәрем [Кәрими, 1996, б. 116]; Иштә, мәдрәсәләрдә әкмәл тәхсил итмеш улан бу мәхдүмнәр тәғлим wә тәрбийәи әүляд илә мәшғуль улсалар, һәм кәнделәре өчен, һәм мәхәллә халқы өчен бик хуш улыр иде [Кәрими, 1996, б. 183] һ.б. Кайбер мәсьәләләргә карата автор үзенең мөнәсәбәтен белдергән вакытта, урыны-урыны белән, шартлы теләк фигыльләрен куллана. Мәсәлән, «Кырымга сәяхәт»тә: Әгәр башқа милләтләрнең сәүдәгәрләре кеби йалғыз мөселман өчен түгел, бәлки ғомум инсан өчен кирәкле нәрсәләр илә сату итсәләр, эстәрсәләр һанке шәһәргә барсыннар, тиҗарәтләре йулында булыр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 317] һ.б.

Шулай итеп, шартлы теләкне белдерә торган җөмләләр, әдәби телгә мөнәсәбәтле рәвештә караганда, асылда, матур әдәбият әсәрләре өчен хас булган бер үзенчәлек булып санала ала, шуңа күрә дә персонажларның хис-кичерешләре, үзара сөйләшү-фикер алышулары һәм аларга карата автор мөнәсәбәтенең катлауланган классик әдипләр иҗатында бу төр җөмләләрнең кулланылуы да активлаша. Әмма төрле әсәрдә төрле төзелештәге шартлы теләк фигыльләре файдаланыла. Мәсәлән, Г. Исхакыйның беренче хикәясе «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1899) әсәрендә шартлы теләк фигыльләре, нигездә, *-са, -р иде* формасында кулланыла: Аллаға шөкер диң, малайлар берлән ашық уйнап, йомырқа уйнап йөрсә, ни эшләр идек. ...Үз кирәгемне белсәм, анда барырға теләмәс идем [Исхакый, 1998, б. 31]; Әй, Алла қушып, бирсәләр иде, үзләре дә ниқадәрле саwаплы булырлар иде [Исхакый, 1998, б. 44] һ.б.

Бу күрсәткечләр белән төзелгән шартлы теләк фигыльләре әдипнең башка әсәрләрендә дә күзәтелә. Мәсәлән, «Кәләпүшче кыз» (1900) хикәясендә: Әти булса уқытыр да иде, кеше дә булыр идек... [Исхакый, 1998, б. 53]. «Бай угылы»нда: Мин булсам, йанымда әллә ниқадәр ақча йөртер идем [Исхакый, 1998, б. 118]. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1904) әсәрендә: Әгәр болай булмаса иде, бу рәсемнәр, бу сурәтләр мине бу көн болай йығлатмайынча, һәммә болғарны көлдерер иде. Әгәр болғарлар бу кешеләрнең йулы берлән китсәләр, бу киләчәк йе-

герме икенче ғасырда безнең бөтен дөньйаға бетүемез иғлан қылынмас иде. Бөтен дөньйаға безнең бер милләт икәнлегемез, безнең бер бәни бәшәргә нинди файдалар китерүемез мөляхәза қылыныр иде [Исхакый, 1998, б. 224] һ.б.

Г. Исхакыйның «Кәләпүшче кыз» әсәрендә *-са, -ачак иде* төзелешендәге шартлы теләк фигыль кулланыла башлый: Йир түгәрәк, йассы түгел, безнең аста, түбән йақта Америка дигән бер зур йир бар диелсә һәм исбат ителсә, Wафаны көлдерүдән башқа эш булмайачак иде [Исхакый, 1998, б. 56]. «Бай угылы»нда да күзәтелә: Чынлап исәпләсәк, Фатыйх байның дүрт-биш йылдан ике асрау малайы булачақ иде [Исхакый, 1998, б. 117] һ.б.

Аңлашылганча, төзелешләре ягыннан караганда, бу әдип шартлы теләкне белдерә торган җөмләләрне, кирәк *-са, -р иде,* яисә *-са, -ачак иде* булсын, гадәттә, тиңдәшләнеп килгән баш җөмләләрне шартны белдерә торган бер иярчен җөмлә белән бәйләнгән хәлдә куллана, әмма *-ачак иде* формасы фикергә катгыйлык төсмере өсти.

Сөйләмә телгә хас булган эмоциональлекне арттыру максатыннан, шартлы теләкне белдерә торган җөмләләрдә Г. Исхакый модаль сүзләр дә куллана: Улсы да шул хәзер җаучы җибәреп сората башласа иде ичмасам, мин айаққа басар идем. ...зинһар, ғазизем, шул җаучы өстенә җаучы җибәрсәнә, мин аңарға бармыйм дип, сиңа барам дип қотылыр идем [Исхакый, 1998, б. 48] һ.б.

Г. Исхакый үзенең аерым әсәрләрендә, эзлекле рәвештә диярлек, билгеле бер шәкелгә салынган шартлы теләкне белдерә торган җөмләләрне куллана. Шуларның шактый активы Г. Исхакый иҗатына кадәр *-дык* формасына нигезләнгән хәл фигыльнең сөйләмә нормасы белән алмаштырылган *-ганга, -ганда, -гач* формаларына тәмамлана торган иярчен җөмләләрдән соң, кушма җөмләнең баш җөмләсендә килә торган *-ачак иде* формасы белән барлыкка китерелә торган шартлы теләкне белдерә торган җөмләләр. Мәсәлән, «Кәләпүшче кыз» да: Қамәр атасыз қалу қайғысын күргәнгә, туғаныннан айырылғанға, шул коннәрдүк анасы да иргә китсә, йараға тоз сипкән төсле булып, атасын сағынып, қарендәшен айап, анасын көнләп сызып бетгәчәк иде [Исхакый, 1998, б. 55]; Йәтимә қыз Қамәр дә туры уқ эшләрен Wафаға тапшырасы булғанғ, Wафа аңарға да, билгеле, башка хатыннарға кылған эшен эшләйәчәк иде [Исхакый, 1998, б. 57]. Қамәр, Вафа өйләнмәгән, мине ала, дип уйлаwы үзенчә туғры булса да, Wафаны мондый уйлаучы қызлар бер Қамәр генә булмағанға, Wафа өчен

бер дуэль булачак иде [Исхакый, 1998, б. 68]. Күренгәнчә, *-ганда, -са, -са да* формалары чиратлашып кулланыла. «Бай угылы»нда: Өч айдан соң Фатыйх байларның кибетләре таратылачак, йортлары сатылачак булганга, искедән дәүләткә өйрәнеп килгән байларга бу көнне күрү бик аwыр булачак иде [Исхакый, 1998, б. 147]. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә: Җәгфәрнең әсәрләре һәр кеше өчен бик кыйммәт булганга, руслар өчен дә үзләренең ничә гасырлар бергә торган wатандашларының, хәтта бәгзе җәһәтләреннән үзләренең мөгаллимнәренең мәгыйшәтләрене белү, тарихлары, музыкалары берлән әшна булу, әлбәттә, матлуб булачак иде [Исхакый, 1998, б. 205]. Г. Исхакыйның кайбер әсәрләрендә *-ганга -ачак иде* формасы белән бирелә торган шартлы теләкне аңлата торган җөмләләр аеруча еш кабатлана, мәсәлән, «Зиндан» хикәясендә әлеге форма вакыйганы алып баруда төп көч булып тора: ...Унбер айга йакын качып йөрү, туктамайынча эшләү мине шактый гына арытканга, шул арада берәр айга күрше шәһәрләрдән берсенә китеп бераз хәл җыйачак идем [Исхакый, 1998, б. 273]; Тәрәзә шактый гына зур булганга, бүлмә көндезләрен караңгы булачак түгел иде [Исхакый, 1998, б. 278]. Мисаллардан аңлашылганча, *-ганга, -гаңда, -гач, -ачак иде* формалы шартлы теләк *-са -ачак иде* формалы җөмләләр белән чиратлаша бара һәм алга таба да шулай дәвам ителә: ...Этап озатканда, мин йөз йегерме чакрымлы үз аwылымызга бик тиз булганда, унынчы көндә кайтып керәчәк идем [Исхакый, 1998, б. 289]; ...Чөнки үзем булмаганда, шул тирәдәге бөтен карагруһ генераллары мине төшерер өчен, бөтен куәтләрен сарыф кылачаклар иде [Исхакый, 1998, б. 293]. Аңлашылганча, хәбәре *-ачак иде* фигыле белән белдерелгән җөмләләр, шартны белдерә торган иярчен кисәктән шактый ерак урнашканга, мөстәкыйль җөмләләр булып күренәләр.

Г. Исхакыйның «Зиндан» әсәрендә *-ганга, -ганда, -ачак иде* төзелешендәге шартлы теләкне белдерә торган җөмләләр рәттән диярлек тезелеп барса да, башка хикәя һәм повестьларында бөтенләй күзәтелми диярлек. Әдипнең «Тормышмы бу?» әсәрендә *-са, -р иде* формалы шартлы теләк фигыльләре кулланыла: Менә, элгәрерәк булса, мин дә шунда сәке йанына утырып кына чәй эчәр идем [Исхакый, 1991, б. 81]; Менә бар да бишәр тиен бирсә, кырык тийен булыр иде [Исхакый, 1991, б. 84]. Күренгәнчә, биредә *-са, -ачак иде* формасындагы шартлы теләкне белдерә торган җөмләләр бөтенләй кулланылмый диярлек. Әдипнең барлык әсәрләрендә дә кире шарт мәгънәсен

алып килә торган *-са да* формасы бик актив файдаланыла. Әлеге үзенчәлек җанлы сөйләмә формаларның киңрәк кулланылуы белән аңлатыла булса кирәк. Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Гафури һ.б.ларның әсәрләрендә урын алган шартлы теләкне белдерә торган җөмләләрнең төзелешен һәм мәгънәсен аңлау өчен, аларның һәр аерым әсәрдә ни рәвешле кулланылуын билгеле бер тәртиптә тикшереп чыгарга кирәк була.

*Кыскача нәтиҗәләр.* XIX гасыр ахыры – XX йөз башында төрле жанр-стильдә язылган текстларда шартлы теләкне белдерә торган җөмләләр, нигездә, түбәндәгечә төзелә: шарт мәгънәсе *-са, -р исә, -мыш исә, -са иде, -ган булса (иде)* формалары, теләк мәгънәсе *-р иде, -ачак иде, -ган булыр иде* формалары белән белдерелә. Шуның белән бергә, аерым әдипләрнең кайбер әсәрләрендә, шарт мәгънәсе *-ганда, -ганга, -гач* күрсәткечле хәл фигыльләр белән дә күрсәтелә ала. Әлеге формаларның һәрберсе үзләренә хас булган мәгънә төсмере белән кулланыла. Классик әдипләр иҗатында җанлы сөйләмдә актив файдаланыла торган *-са* кушымчасы чагылыш тапкан тотрыклы тезмәләр һәм кабатлана торган формалар ныклы урын ала. Бу күрсәткечләрдән автор үзенең аерым бер әсәренең образлар системасына туры килгәннәрен сайлап ала, тасвир чарасы итеп күтәрә. Димәк, шартлы теләкне белдерә торган формалар да функциональ-стилистик вариантлылык хасил итә дип әйтә алабыз.

*Ният фигыль.* Хәзерге татар әдәби телендә ният модальлеге, мөмкинлек, кирәклек, тиешлек, фараз итү модальлекләре кебек үк [Татар грамматикасы, 2002, б. 167–175], наклонение дип каралмый, ягъни татар телендә хикәяләү, боеру, теләк, шарт наклонениеләре кебек формалашып җиткән грамматик категория дип саналмый, әмма ният мәгънәсен белдерә торган төрле формаларның булуы күрсәтелә [Татар грамматикасы, 2002, б. 173–175; Хисамова, 2006, б. 270]. Шуның белән бергә, Х.Р. Курбатов җитәкчелегендә дөнья күргән «Хәзерге татар әдәби теле» хезмәтендә [Хәзерге татар..., 1965, б. 243–247] һәм фигыльне гомумтюркологик планда тикшерүчеләр [Юлдашев, 1965, с. 214–216], шулай ук – татар теле диалектларын өйрәнүчеләрнең хезмәтләрендә [Юсупов, 2004, с. 501–518] ният фигыль мөстәкыйль наклонение (наклонение намерения) дип җентекләп тикшерелә, ягъни сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерә торган модальлек функциональ-семантик категориясенең бер күрсәткече булып санала.

Бу хезмәтләрдә ниятне белдерү мәгънәсенең *-макчы, -макчы иде, -макчы бул- (-мак бул-)* формаларына нигезләнүе ассызыклана, шулай ук татар әдәби телендә һәм сөйләшләрдә *-рга/-маска, -асы, -ачак* формасы нигезендә төзелгән төрле аналитик формаларның да ният модальлеген белдерә алуы күрсәтелә.

Тарихи аспектта карaганда, *-макчы, -макчы иде, -макчы икән* формаларының хикәя фигыль итеп бирелүе мәгълүм [Гиганов, 1801, с. 93; Нугайбәк, 1911, б. 80]. Л. Җәләй хезмәтендә, *-мак бул* теләк фигыльнең аналитик, *-макчы, -мәкче* синтетик формасы «*...-мак, -мәк* кушымчалы исем фигыльгә *-чы, -че* кушымчасы ялгап, теләк төшенчәле фигыльләр ясау XX йөздә системалы төс ала», – дип аңлатыла [Җәләй, 2000, б. 271–272]. Әмма әлеге формаларның «Бабурнамә» текстында (XVI) шул ук теләк мәгънәсендә файдаланылуы күрсәтелә [Благова, 1994, с. 353]. Иске татар телендә язылган истәлекләрне тикшерүчеләрнең хезмәтләреннән күренгәнчә, ният наклонениесе аерып алып өйрәнелми.

Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл Бистәви әс-Сәгыйди» (1845, 1889) әсәрендә *-мак* кушымчалы исем фигыльләр кулланыла: ...Буйлә мәхкәм дотмақың аслы нәдер, ...би иман китмәкнең ахыр афәте [Каргалый, 1889, б. 3]; ...һәм рәсүлең сөннәтелә истинан (таянып) / Әйләмәкне рузи қыйл ба дил-ү-җан [Каргалый, 1889, б. 5]; ...қоллық итмәк – эше дорыр бәндәнең [Каргалый, 1889, б. 9] һ.б.

*-мак* кушымчалы фигыль сыйфат фигыль мәгънәсендә файдаланыла: ...Шәрғдә көфер улды кисмәклек өмид [Каргалый, 1889, б. 3] һ.б.

*-мак* кушымчалы фигыль инфинитив мәгънәсендә кулланыла: ...Қабул итде ушал сачы бөридә / Аны бәнд итмәккә уйқуларында [Каргалый, 1889, б. 6]; ...Ки лязимдыр безә кәррат-мәррәт / Мөбәрәк рухына вирмәк салават [Каргалый, 1889, б. 7] һ.б.

Әлеге форма, сүз җаена туры килеп, максат-ният мәгънәсендә аңлашыла: …хәян иимәкдә (тере калу өчен) қапқасын қойма итәр [Каргалый, 1889, б. 3]. Бу мәгънә *-мак ирде* аналитик форма белән тагын да ачыграк сиземләнә: ...Тохымыны җәмғ әйләмәк ирде эше [Каргалый, 1889, б. 3].

Г. Кандалый иҗатында да *-мак* формасы төрле килеш кушымчалары алган исем фигыльләр кулланыла: ...сағынмақдин бәйет йаздым [Каргалый, 1889, б. 90]; ...иген икмәк бирер икмәк [Каргалый, 1889, б. 95]; ...Нә дәклү қарным ач улса / Туйар бер ләкмә йимәкдин / Wә иллә күзләрем туймаз / Туғаным, синен күрмәкдин [Каргалый, 1889, б. 145] һ.б.

Лексик чаралар белән куәтләнгәндә максат-ният мәгънәсе белдерелә: ...Бәнем ғарзым (теләгем) үзең күрмәк / Күреп нәчеклекең белмәк (б.129), ...Сәне күрмәк деләр күңлем [Каргалый, 1889, б. 145]. *-мак* формалы фигыль *өчен* бәйлеге белән кулланылганда да шул ук мәгънә аңлашыла: ...Сәне күрмәк өчен гирйан (күз яше түгүче) улыпмын [Каргалый, 1988, б. 156] һ.б.

*-мак* формалы инфинитив кулланыла: ...Морадымдыр ирешмәккә / Синең илә күрешмәккә, / Дәхи әхуаль сорашмаққа / Хода нәсыйб әйләсен, җаный [Каргалый, 1988, б. 128]. *-мага* формалы инфинитив күзәтелә: ...Бәне сайрамаға былбыл йаратды [Каргалый, 1988, б. 153] һ.б.

«Сахибҗәмал» поэмасында *-макда* формалы исем фигыль кулланыла: Торып йахшы гурничәдә / Тәмам ғомрең буйынча да / Сөйешмәкдә, уйынчада / Бушана белмәссең бер дә [Кандалый, 1988, б. 398]. Бер үк шигъри юлларда өч мәртәбә *-мәк* формасы кабатлана да, дүртенчесендә *-мәкдә* дип нәтиҗә ясала: Самоварларда чәй эчмәк / Сәwешеп төн аша кичмәк / Нәфис төрле кийем печмәк / Кимәкдә үтә ғомердә. Алға таба *-макта* формасы гына кабатлана: Кичә-көндез бизәнмәдә / Кийенмәкдә, төзәнмәкдә / Булып күркәм чибәрлекдә / Торып мелла-ғалим ирдә [Кандалый, 1988, б. 399, 424]. Әлеге үзенчәлекне Л. Җәләй: «*..-мак, -мәк* кушымчасына урын-вакыт килеше *-да, -дә, -та, -тә* өстәп, дәвамлы хәл фигыль ясау булган», – дип аңлата [Җәләй, 2000, б. 270].

XIX гасырның икенче яртысында язылган Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәренең тезмә өлешендә (1879) *-сам кирәк* формасы кирәклек-ният мәгънәсен белдерә: ...Бер уй қыйлсам кирәктер / йортым җыйсам кирәктер / Қызым қушып Таһирға, туйын қыйлсам кирәкдер [Татар әдәбияты, 1957, б. 297] һ.б.

Традиция дәвам ителеп, Г. Кандалый шигырьләрендәге кебек үк, Г. Тукай иҗатында да *-мак* кушымчалы исем фигыльләр эзлекле кулланыла: ...У гүзәл ғыйшқында әшғар сөйләмәкне халисән... [Тукай, 1985, т. 1, б. 58]; ...Кичә-көндез уйнамақ та уйнамақ / Уйнамақның ахрыны йуқ уйламақ [Тукай, 1985, т. 1, б. 77] һ.б.

*-мага* һәм *-мак* кушымчалы инфинитив кулланыла: ...Wақыт қортылмаға бу пәнҗәләрдән / Wақыт ычқынмаға эскенҗәләрдән [Тукай, 1985, б. 97]; ...Ничек тормақ тийеш, дустым? – дисеңме [Тукай, 1985, т. 1, б. 31].

«Ләззәт һәм тәм нәрсәдә?» шигырендә *-макда* кушымчалы исем фигыль, ун мәртәбә кабатлангач, *-у* формасы белән чиратлаштырыла:

...қочмақтамы, очмақтамы, эчмәктәме, кичмәктәме, улмақтамы, сикермәктәме, кикермәктәме, уйнаудамы, уйлаудамы [Тукай, 1985, т. 1, б. 161]; ...Сабый wақтын сағынмақта һәр шағыйрь дә [Тукай, 1985, т. 1, б. 205] h.б.

*-мак* кушымчалы фигыль өчен бәйлеге белән кулланылганда, максат-ният мәгънәсе белдерелә: ...Барча күрешмәк өчен йөгерделәр [Тукай, 1985, т. 1, б. 275]; ...Көйәм бирмәк өчен хөрлек, азатлықлар хатыннарға [Тукай, 1985, т. 2, б. 9]; ...Тик Ходай хәзер урынны сайлый ул азмақ өчен [Тукай, 1985, т. 2, б. 25] h.б.

Дәверләр узып килә торган традицион формаларны кулланылу белән бергә, әлегә кадәр К. Насыйри кыйссаларында кулланылса да, тезмә әсәрләрдә сирәк күзәтелә торган *-мак бул-, -макчы бул* формалары белән теләк-ният мәгънәсе белдерелү Г. Тукай иҗатында тасвир чарасына әверелә : ...Шүрәле фөрьйат итәдер, аудан ычқынмақ була, / Һәм дә ычқынғач, йегеткә бер-бер эш қылмақ була... [Тукай, 1985, т. 1, б. 171]; ...Очырмақчы булсам былбыл күкрәгемнән / Әллә ничек, мыр-мыр итеп, мәче чыға... [Тукай, 1985, т. 1, б. 176] h.б.

Г. Тукайның еш кына боерык фигыльләргә *-чы* кушымчасы кушылган боерулы-теләкне белдерә торган формаларны (булчы син миңа мөрит [Тукай, 1985, т. 1, б. 124]; ...Тукътап торчы әзерәк, ...чалмаң ишелгән, чорначы [Тукай, 1985, т. 1, б. 125]; Тәңре! чигерче йәшемне [Тукай, 1985, т. 1, б. 205] h.б.) файдалануы күзәтелгәнгә, *-мак* формасына *-чы* кушылу гадәти булып кабул ителә, әмма *бул* ярдәмлеге белән бергә кулланылуы игътибарны җәлеп итә. Л. Җәләй болай дип искәртә: «*-мак бул* ярдәмче фигыль кушылмасы белән ясалган аналитик теләк фигыль. Хәзерге әдәби телдә теләк төшенчәсе синтетик форма *-макчы, -мәкче* кушымчасы белән әйтемләнә. Бу форманың актив кулланылышын М. Гафури һәм Г. Тукай әсәрләреннән башлап кына күрергә мөмкин... Хәзерге татар телендә *бул* ярдәмче фигыле белән максат, теләк, ният (намерение) төшенчәсен бирә торган өч төрле тезмә фигыль формасы бар: ул калага бармак булды, ул калага бармакчы булды, ул калага барырга булды», – дигән мисалларның беренче икесен теләк-ният, соңгысын – максат фигыль, – дип атый [Җәләй, 2000, б. 271, 273]. Г. Тукайның чәчмә әсәрләрендә дә *-мак эстәү, -макче бул* ният фигыльләре файдаланыла. «Мохарәбә вә Государственная дума» (1906): ...Бонлар исә Русийәи белмәйән wә белмәк эстәмәйән чиновниклар улмай, ...крестьйаннар исә, ...кирәкле йирләрә тәүзиғ итмәк эстәйүрләр [Тукай, 1985, т. 3, б. 9]. «Килештерүче» язмасында (1909):

...син хатыныңны җуатмакчы буласың. ...мин бит сезне татулаштырмакчы булам, ...мин изге нийәттә ич, сезне килештермәкче булам [Тукай, 1985, т. 4, б. 93–95]. «Исемдә калганнар»да (1909): ...Мин қыш көннәрендә төнлә йаланайак, күлмәкчән көйенчә тышқа чығам икән дә бераздан, өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән [Тукай, 1956, б. 13] һ.б. Галимнәр белдергәнчә, *-мак бул-* формасы шарт фигыль һәм хәл фигыль формалары алган хәлдә файдаланылса да, ешрак хикәя фигыль күрсәткече белән кабатлана һәм, ният-теләк мәгънәсеннән бигрәк, ният-карар мәгънәсен белдерә [Юлдашев, 1965, с. 219].

Тезмә әсәрләрдән аермалы буларак, ният фигыльнең нигезен тәшкил итә торган *-макчы* формасы, XIX гасыр ахыры – XX йөз башында язылган кыйссаларда ук кулланыла. Бу фигыльнең мәгънәсе, хәзерге әдәби телдә һәм сөйләшләрдәге кебек үк, күп төрле аналитик формаларда да тәгъбир ителә һәм алар төрле әдипнең иҗатында төрле дәрәҗәдә чагылыш таба, ягъни аерым әсәрләрдә төрле ешлыкта кабатлана, ягъни аны формалашып җиткән грамматик категория-наклонение дип санарлык ныклы җирлек барлыгы күренә. К. Насыйриның сәнгатьле проза әсәрләреннән «Кырык вәзир кыйссасы»нда (1868) *-макчы* формасының II зат күплек саны файдаланыла: Карчык әйтде: Мин қурқамын, сезләр һәм ул йаңа патшаға табыйғларсыз. Патшаны тотып китермәкчесез, – диде [Насыйри, 1975, б. 244]. *-макчы бул-* формасы да кулланыла: Бер заманнан соң патша үзенең хәрәменә килеп, уғыланның хәлен атасыннан сорамақчы булды [Насыйри, 1975, б. 244] һ.б.

К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда (1881) *-макчы бул* тезмәсе *-мак бул-* белән чиратлаша: ...әйләнеп китмәкче булғаннар иде [Насыйри, 1974, б. 261]; ...Қойының диварына бер миқдар тотынып торырлық җир йасамақчы була [Насыйри, 1974, б. 279]. Шул ук вакытта *-макчы иде* формасы да кулланыла: ...бер җиргә барып ашамақчы иде [Насыйри, 1974, б. 275]; ...бер тарафка қачмақчы иде [Насыйри, 1974, б. 278]. *-мак* һәм *-мага* формалары актив кулланыла, *-макчы бул-* күрсәткече белән чиратлаша, теләк-ният мәгънәсен белдерә торган күпсанлы сүзләр белән дә бәйләнештә килә алалар: *-мак эстәү, -мага тели, -мага ният, -мак касды, -мага рәгъбәт итү, -мага хәмлә кыйлу, -мага һиммәт баглау.* Мәсәлән: ...ғыйлем wә хикмәт wә мәғрифәт арттырмақ қасды белән бөтен дөньйаны гизмәгә нийәт итде [Насыйри, 1974, б. 209]; ...һәркем мең җан белән хаммамны күрмәгә арзу қыйлыр иде [Насыйри, 1974, б. 215] һ.б. К. Насыйри әсәрләрендә ният мәгъ-

нәсе I зат теләк фигыле һәм *ди-* фигыле белән дә белдерелә: ...әгәр анаңны ничек үтерим дисәң, ...мин сине ничек итеп алыйм дисәң, [Насыйри, 1975, б. 224]; – дип әйтим дисә, ...айу кебек мығырдар иде [Насыйри, 1974, б. 274] һ.б.

Ә. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрендә (1879) *-макчы бул* ният фигыле файдаланыла: дәрвишкә мең алтын бирмәкче булып торғанда [Татар әдәбияты, 1957, б. 289]; ...Таһир илә Зөһрә бакчаға китмәкче булдылар [Татар әдәбияты, 1957, б. 296]. *-мак бул* формасы белән чиратлаша: ...Зөһрәне Таһирға бирмәк булғанын сөйләде [Татар әдәбияты, 1957, б. 300] һ.б. Шул ук теләк-ният мәгънәсе *-мак касыд кылу* формасы белән белдерелә: ...әгәр атам мине ғайре кешегә бирмәк қасыд қылса,.. [Татар әдәбияты, 1957, б. 293]. Әлеге мәгънә *-мага касыд кылу* кушмасы белән белдерелә: ...саз wә сорнай тартмакны өйрәнмәгә қасыд қыйлды [Татар әдәбияты, 1957, б. 293] һ.б. Әсәренең тезмә өлешендә кирәклек-ният мәгънәсен белдерә торган *-сам кирәк* формасы чәчмә өлешендә дә кабатлана: ..әүwәлге вәғдәсе буйынча, Зөһрәне Таһирға бирсәм кирәкдер, диде [Татар әдәбияты, 1957, б. 300] һ.б. Аңлашылганча, тезмә әсәрләрдән аермалы буларак, чәчмә әсәрләрдә ният-теләк төшенчәсенең күп төрле формалар белән файдаланылуы күренә.

Татар прозасын хикәяләүнең икенче төрен башлый торган М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә, *-мак эстәү* формасы бик активлаша: Йәшь әфәнде чуқдан бу кеби кеше илә таныш улмақ эстәйүр иде [Акъегет, 1886, б. 8]; ...Менланың кердекене белеп wә йәнә бер күрмәк эстәп, [Акъегет, 1886, б. 10]; ...сүзләшмәк эстәмәде исә дә [Акъегет, 1886, б. 16] һ.б.

Аңлашылганча, әлеге әсәрдә теләк-ният мәгънәсе, нигездә, *-мак эстәү* аналитик формасы белән белдерелә, *-макчы* күрсәткече кулланылмый. *-макчы бул-* формасы Ә. Уразаев-Кормашиның кыйссаларында файдаланылуы күзәтелгән иде: ...дәрвишкә мең алтын бирмәкче булып торғанда [Татар әдәбияты, 1957, б. 289]; ...Әмма бер көн Таһир илә Зөһрә бақчаға китмәкче булдылар [Татар әдәбияты, 1957, б. 296] һ.б.

Беренче драма әсәрләрендә дә ният мәгънәсе *-макчы бул-, -мак бул-, -макчы иде-* формалары белән белдерелә. Г. Ильясиның «Бичара кыз» драмасында (1887): ...бу арада қызлар җыймақчы булабыз [Татар әдәбияты, 1957, б. 559]. Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» драмасында (1888): Биби әби китмәк булғанда [Татар әдәбияты, 1957, б. 580];

...мин ишек қақтырмақчы идем [Татар әдәбияты, 1957, б. 581] һ.б. «Морад Сәлимов» драмасында (1905): ...мин бу кичә пойезд илән чықмақчы идем, юл хәраҗәтенә ақчам йуқ, шул сәбәптән җәнабеңезгә барып бер йөз тәңкә қарыз алып тормақчы идем [Татар әдәбияты, 1957, б. 603]. «Комедия Чистайда» драмасында (1895): ...шулай қыланып ул кеше күзенә йахшы күренмәкче була [Татар әдәбияты, 1957, б. 637]. Мисаллардан күренгәнчә, ешрак *-макчы бул-* формасы кабатлана. Шуның белән бергә, әлеге әсәрләрдә К. Насыйриның сәнгатьле прозасында бер-ике мәртәбә күренеп киткән *-асы бул-* һәм *-ыйм дип* формаларының да ният мәгънәсе алып килүе күзәтелә: Менә бервакытны мине әниләр кияүгә бирәселәре булды [Татар әдәбияты, 1957, б. 557]; ...Маһитапны қызық итим дип, талақ қылған, дигән [Татар әдәбияты, 1957, б. 577]. Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасында (1907): Исмәғыйльне аталары өйләндермәкче булалар ди [Камал, 1978, б. 44]. «Беренче театр» комедиясендә: ...Қара син аны, анда йалғыз ғына қызлар қарарға бармақчы була [Камал, 1978, б. 66] һ.б.

Әлеге мисал-күрсәткечләргә нигезләнеп түбәндәге нәтиҗәне чыгарырга мөмкин: өйрәнелә торган чорда, әдәби телнең халыклашкан варианты белән язылган текстларда ният-теләк мәгънәсе, асылда, *-макчы бул, -мак бул, -мак иде* формалары белән, ә инде җәдиди госманлы варианты белән язылган текстларда шул ук мәгънә, асылда, *-мак эстәү* тезмәсе белән бирелә. Әмма *-мак эстәү* формасы З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә *-мак нияте илә* кебек үк бары бер мәртәбә кулланыла: Хәдичә туташ Муса әфәндийе күрмәк эстәдегеннән,... [Бигиев, 1991, б. 234]; ...Муса әфәндейә хатын булмақ нийәте илә бәлдәи Қазанға килдем [Бигиев, 1991, б. 249]. Шул ук авторның «Гөнаһе кәбаир» романында *-макчы бул* формасындагы ният фигыль кулланыла: Узған йылда да Қазанға уқырға йибәрмәкче булған идем [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 256]; Без дә менә бу йекетне ...ул мәдрәсәйә қуймақчы буламыз [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 258]. Бу әсәрдә шулай ук ният мәгънәсен белдерә торган аналитик формалар куллану да дәвам итеlә: Балаңны-уғлыңны нә тариқа нә қыйлурға ирадә қыйласың [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 262]. Хатны Яққуб Ғалийевкә тапшырмақ нийятлә ...өйүдән хоруҗ әйләде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 264] һ.б.

Р. Фәхретдиннең сәнгатьле проза әсәрләрендә ният мәгънәсе эзлекле рәвештә *-мак ул-, -ачак ул-* формалары белән тәгъбир ителә. «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә: Төркийә, Мисыр мәмләкәтләренә

йөрмәк, Қытай wә Йапун өлкәләрене күрмәк, Һиндстан wә Җәва туфрақларыны зийарәт итмәк уладыр идем, ...Иң мөқаддәм үземнең туған урыныма қайтып ата wә анам қаберләрене зыйарәт итәчәк улдым [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 268]; Имде, тимер йул урынына пароход илә Уфа дийә, Тыйһран шәһәренә йулланачақ улдым [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 286] Әдипнең бу әсәрендә ният мәгънәсе бер-ике урында *-мак нияте илә, -ырга эстәдем* формалары белән дә бирелә.

Р. Фәхретдиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә дә ният мәгънәсен белдерә торган фигыльләр шушы тәртиптә кулланыла: Шуның өчен низамға муафыйқ итеп, сиңа һич улмағанда йегерме мең тәңкә wасыйәть итеп йаздырмақчы уламын – дидегендә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 341]. Бу әсәрдә дә ният мәгънәсе *-мак эстәү* һәм *-мак нияте илә* формалар белән дә бирелә: ...барырға риза улмамақ эстәде исә дә, ...Әсманы күңел wә хәтер ачып килсен дийә җибәрмәк эстәр иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 328]; ...тәрбийә ханә хақында бер рисалә йазмақ нийәте илә сорадығыны белдегендә [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 336] һ.б.

Шулай итеп, К. Насыйри, Ә. Уразаев-Кормаши әсәрләрендә кулланыла башлаган *-макчы бул-* формалы ният фигыль М. Акъегет, З. Бигиев, Р. Фәхретдин әсәрләрендә, нигездә, *-мак ул-* формасы буларак файдаланыла һәм ният мәгънәсе тагын *-мак эстәү, -мак нияте илә* формалары белән дә тәгъбир ителә.

Ният фигыльнең *-макчы бул-* формасы Ф. Кәриминең хикәяләрендә активлаша. «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә: Салих бабайдан хикәйәт сөйләтмәкче булып йалwарсақ та, [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 221]. «Җиһангир мәхдүмнең ауыл мәктәбендә укуы» хикәясендә: ...уғылыны бик йахшы уқытмақчы була [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 230]; ...ғыйльме сарыф илә ғыйльме нәхүне бик йахшы уқытмақчы иде [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 231]. Мисаллардан күренгәнчә, *-макчы бул-* формасы берлек һәм күплектәге һәр өч зат кушымчасы алган хәлдә дә шулай ук шарт фигыль белән, хәл фигыль формалары алган хәлдә дә кулланыла, *-макчы иде* һәм *-ачак бул-* формаларына караганда шактый еш кабатлана. *-мак нияте* тезмәсе сирәгәя: ...әүwәлән үз мәктәбендә бераз уқытып, аннан соң бер зур мәдрәсәгә җибәрмәк нийәтендәдер [Татар мәгърифәтчелек..., 1979, б. 230].

Ф. Кәриминең башка әсәрләрендә *-макчы бул-* формалы ният фигыль сирәгрәк файдаланыла. «Нуретдин хәлфә»дә дә, «Бер шәкерт илә

бер студент»та да *-макчы бул-* бер-ике урында гына күренә: ...һәр нәрсәне татарчаға тәрҗемә итеп, үз телебездә уқытмақчы булалар икән [Кәрими, 1996, б. 48]; Нуретдин хәлфә шулай байтақ хисаплап утырғач, тағын қулындағы китабын ачып уқымақчы булды [Кәрими, 1996, б. 70]. Әдипнең әлеге әсәрләрендә ният-максат мәгънәсе тагын *-мак иде, -ачак бул* формалары белән дә тәгъбир ителә: ...дөньйа wә ахирәт өчен аннан файдалы сүзләр ишетмәк wә татлы бер мөсахәбәт итмәк иде [Кәрими, 1996, б. 37]; ...бераз китап моталәгә итәчәк булды [Кәрими, 1996, б. 59] һ.б.

Ф. Кәриминең «Морза кызы Фатыйма» әсәрендә *-макчы бул-* формалы ният фигыль берникадәр ешрак файдаланыла: ...гүйә ғазимат илә генә күңел өчен Мостафадан исәнлек-сағлык сорамақчы буладыр иде [Кәрими, 1996, б. 82]; ...сөйенечеңезне изһар итмәкче буласыз ахрысы [Кәрими, 1996, б. 85]. *-макчы бул-* формасы зат кушымчалары белән активрак булсалар да, шарт фигыль формасын алу очраклары да күзәтелә: ...күшегенә кереп йатарақ, бераз йоқлап истирахәт итмәкче wә хәл җыймақчы булса да… [Кәрими, 1996, б. 101]; ...бик әсәрләнеп бер нотық сөйләмәкче булса да… [Кәрими, 1996, б. 104]. *-ачак бул-* тезмәсе дә шул ук формада кулланыла: ...Фатыймаға бер сүз әйтәчәк булса, [Кәрими, 1996, б. 110]; ...Истамбулға китәчәк булсалар, иртәсе көн кәнделәре дә ошбу пароходқа иңәчәк булдылар [Кәрими, 1996, б. 114]. Әдипнең әлеге әсәрләрендә ният мәгънәсе *-мак эстәү* формасы белән дә бирелә:... Ғайнетдиневкә биреп уқытмақ эстидер [Кәрими, 1996, б. 65]; ...wә үзенең башқа мөселман депутатлары илә дә танышмақ эстәдекен бәйән итеп... [Кәрими, 1996, б. 126]. Шул ук *-мак эстәү* формасы Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә дә дәвам ителә: Шакир әфәнде, ...локомобиль (пар машинасы) wә саир аләтләр алмақ эстәйүр иде [Кәрими, 1996, б. 166]; Заныма күрә, русча йәхуд французча белсәләр дә, кәнде лисаннарыннан башқасы илә қонышмақ эстәмәйүрләр булса кирәк [Кәрими, 1996, б. 166] һ.б. Әлеге юлъязмаларда *-ачак бул-* формасы да еш кабатлана: Әгәр көне килдекдә билет алачақ булырса, әксәрийән сатылып бетмеш булыйур [Кәрими, 1996, б. 182]; ...имамнардан соралачақ булырса [Кәрими, 1996, б. 184] һ.б. Аңлашылганча, Ф. Кәриминең юлъязмаларында ният мәгънәсе, нигездә, *-мак эстәү* һәм *-ачак бул-* аналитик формалары белән белдерелә, *-макчы бул-* формасы бөтенләй кулланылмый. *-ачак бул-* ниятне аңлатуы белән бергә, эшнең тәгаен үтәлергә тиешлеген дә белдерә.

Әлеге әсәрләр белән бер үк вакытта басыла башлаган Г. Исхакый хикәяләрендә *-мак эстәү* формасы бөтенләй кулланылмый диярлек, авторның язма традиция ныграк сакланган кереш сүзендә генә берничә мәртәбә кабатлана. Мәсәлән, А.С. Пушкинның «Капитан кызы» әсәрен ни өчен тәрҗемә итүен аңлатканда: ...әсәрләренең берсе мәшһүр Пугачев wақыйғасын тасвир қыйлған хикәйә булдығындан мин дә қарийәләремә тәқдим қыйлмақ эстәдем [Исхакый, 1902, б. 3]. «Бай угылы»ның беренче басылуына мөкаддимә дигән кереш сүздә: Ләкин, бердән, бала wақытымда йазылған бер әсәремнән балалық фикеремне йуғалтасым килмәдекеннән, икенчедән, ислях wақытында романымның маэле йуғалачақ булдығыннан, иске қосурлары, иске хәлләре берлән мәйданға қуймақ эстәдем. ...Милләтемездә шул мәсьәләне ислях фикере уйанмасмы дип, мин шул эшләремезне булдыра алдығым қадәр күрсәтмәк эстәдем [Исхакый, 1998, б. 13]. Әдипнең кайбер әсәрләрендә, мәсәлән, «Очрашу яки Гөлгыйзар»да *-ачак бул-* эзлекле булып бара, ә «Кәләпүшче кыз» хикәясендә «Хөрмәтле укучым» дип бирелгән кереш сүздә ул *-ачак улдым* булып кулланыла: ...алдағым бер хат диққатемне җәлеп итдегендин, уқучыларыма күрсәтер өчен, бергә бастырачақ улдым һәм китабымның ахырына ғыйлаwә қыйлдым [Исхакый, 1998, б. 51]. Гомумән алганда, әдипнең барлык әсәрләрендә дә ният мәгънәсе, асылда, *-макчы бул-* формасы белән белдерелә. Әлеге форма зат кушымчалары алган хәлдә дә, шарт фигыль һәм хәл фигыль формалары алган хәлдә дә файдаланыла. *-макчы* күрсәткече ялгыз хәлдә сирәк күзәтелә: Дөресте генә Зөһрә Камәрне сатып бераз акча алмақчы да, Қамәрнең рәхәтен җуйып мескинә қызны тағы әллә нинди бәлаләр, хәсрәтләр чигәргә мәҗбүр қылачақ иде [Исхакый, 1998, б. 66]; Без Гөлғыйзар берлән, ни дә булса, үземезчә эшләмәкче, алар артымыздан килсәләр дә, әһәмийәт бирмәйенчә, гостиницаға керәчәк идек [Исхакый, 1998, б. 104]. *-макчы иде* формасы да *-макчы бул-* тезмәсенә караганда шактый сирәк файдаланыла: Қамәр берлә Ғабделәхәт хақында ни эшлисен кистермәсә дә, Қамәрне үзе берлә бергә алмақчы, ...асрауға бирмәкче иде [Исхакый, 1998, б. 52]; ...сораучыны да ошатканға, шул көннәрдүк китмәкче иде [Исхакый, 1998, б. 55]. *-макчы бул-* формалы ният фигыль Г. Исхакыйның барлык әсәрләрендә дә кулланыла, әмма төрле әсәрдә төрле ешлыкта кабатлана, «Кәләпүшче кыз», «Бай угылы» әсәрләрендә әлеге форма аеруча эзлекле булып тезелеп бара: ...Кәрим өчен Зәләл исемле бер қарендәш қызларыны сөйдермәкче булдылар [Исхакый, 1998, б. 131];

...шул сәғаттүк приказчикларны йибәреп эзләтмәкче булсалар да [Исхакый, 1998, б. 135] һ.б.

Г. Исхакыйның сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә ният мәгънәсе *-рга -маска* формасы нигезендә төрле ярдәмлекләр белән аналитик тезмәләр рәвешендә дә белдерелә. Әдип үзенең беренче хикәясендә, теләк-ниятне белдерер өчен, мишәр диалектына хас булган [Юсупов, 2004, с. 509] *-ырга кели* формасын еш кабатлый: ...Кеше белүе безгә түгел, әнә шул, шуңарға қызығып уқытырға келисең [Исхакый, 1998, б. 32]; Син ашарға-эчәргә сорамыйсың, балаңа фарыз булған ғыйлемне үгрәтергә келисең [Исхакый, 1998, б. 33]. Әдипнең башка әсәрләрендә *-ырга кели* формасы кулланылмый булса кирәк. Беренче драма әсәрләрендә дә ният-теләк мәгънәсе *-макчы бул-* һәм *-ырга тели* тезмәләре белән белдерелә. Мәсәлән, «Өч хатын берлән тормыш» драмасында: Әсма озатырға теләсә дә, чығып өлгерә алмый [Исхакый, 1998, б. 78]. ...Шәйхетдиннәр сеңелләрен бирмәкче булғаннар иде, қызлары ...мине маймылға бирмәкче буласызмени? – дип җылаған [Исхакый, 1998, б. 84]; Сорур аны үтеп чықмакчы булған [Исхакый, 1998, б. 85] һ.б.

Г. Исхакый әсәрләрендә ният мәгънәсе тагын К. Насыйри әсәрләрендә шактый актив кулланыла торган I зат теләк фигыле һәм *ди-* фигыле белән дә белдерелә: Фатыйма: Уғылым, бүген китәм дигән идем [Исхакый, 1998, б. 42]. Ният фигыльнең бу формасы драма әсәрләрендәге диалогик сөйләмдә активрак кулланылуы күзәтелә. Шулай да Г. Исхакыйның барлык әсәрләрендә ният-теләк-тиешлек мәгънәсе, асылда, *-ырга* формасы һәм төрле ярдәмлекләр белән белдерелә.

Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, М. Гафури кебек классик әдипләр иҗатында да ният мәгънәсе төрле ешлыкта кабатланып кулланыла. Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә ният мәгънәсе *-мак бул-, -макчы бул-, -макчы иде, ачак бул-, ырга теләү, -ыйм, -им дип* формалары белән белдерелә, әмма «Гыйшык корбаннары» хикәясендә *-мак бул-* формасы актив файдаланыла: ...Ғалимәне қызғаналар, аналарыны тәсәлли хатир итмәк булалар иде [Ибраһимов, 1974, б. 466]; Ул үзенең бу йығлаwы, бу қадәрле күз йәше түгүе белән күңелендәге қайғыларыны җуып төшермәк, ағызмақ була иде [Ибраһимов, 1974, б. 467]. «Яшь йөрәкләр»дә *-макчы* кушымчасы кулланыла: Адәм аwылдан қотыла алмый ...ә ул шул чақлы уқығаннан, йөргәннән соң тағы аwыл мужигы булмақчы [Ибраһимов, 1975, б. 58]; ...Миңа ичмаса хәтер өчен дә: «Шулай итмәкчемен» – дип аwыз ачмый [Ибраһимов, 1975, б. 279] һ.б.

Ф. Әмирханның «Татар кызы» хикәясендә (1909): ...бу көн үк бер қарчық арқылы қызға бик сағынып, бик сарғайып сәлам күндермәкче булды. ...Қарт бай да wақыты белән моны икенче хатынлыққа сораткмақчы булды [Әмирхан, 1984, б. 54] һ.б.

*Кыскача нәтиҗәләр.* XIX гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән матур әдәбият стиленең барлык жанрларында ният фигыль дә кулланыла. Поэзия әсәрләрендә исем фигыль күрсәткече булган *-мак* формасының *өчен* бәйлеге белән максат-ният мәгънәсендә файдаланылуы күзәтелә, *-мак бул* кушмасы гамәлгә куела һәм *-макчы бул* аналитик рәвештә Тукай иҗатында эзлекле кулланыла. Проза әсәрләрендә, К. Насыйри кыйссаларыннан башлап, ният төшенчәсе *-макчы* күрсәткеченнән башка, хәзерге әдәби телдә һәм сөйләшләрдәге кебек үк, төрле аналитик формалар белән дә тәгъбир ителә: *-макчы бул-, -макчы иде-, -мак бул-, -ырга бул-, -ачак бул-, -ырга кели, -ырга тели, -мак тели, -мага тели, -ыйм/-ыйк ди-,* шуның белән бергә, өйрәнелә торган чорда язылган текстларда, аналитик формаларның тагын да күбрәк кулланылуы күзәтелә: *-макчы ул-, -мак ул-, -ачак ул-, -мак эстәү, -мага ният илә, -мак касды, -мага рәгъбәт итү, -мага хәммлә кылу, -мага һиммәт баглау, -ырга эстәү, -ырга ирадә* һ.б. Шулай итеп, ният мәгънәсен белдерә торган формалар, өйрәнелә торган чорда, угыз һәм кыпчак телләренә хас булган ике әдәби тел нормасында кулланыла, графо-орфографик, морфологик һәм синтаксик вариантлылык хасил итә. Әлеге күрсәткечләрнең файдаланылуында, билгеле бер дәрәҗәдә эш бүленеше күзәтелә, ягъни аерым әдипләрнең кайбер әсәрләрендә ният мәгънәсен белдерә торган формаларның яки берничәсе, яки, нигездә, берсе генә актив кабатлана. Мәсәлән, М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында *-мак эстәү* тезмәсе генә эзлекле кулланыла, димәк, әлеге фигыльнең кулланылышында да функциональ-стилистик вариантлылык хасил була.

Хронологиягә бәйле рәвештә караганда, язма традицион-аналитик формаларның пассивлаша баруы күзәтелә. Классик әдипләр иҗатында ният мәгънәсе, нигездә, *-макчы* һәм *-ырга* кушымчаларының *бул* һәм *иде* ярдәмлекләре белән бергә төзелгән формада белдерелүе эзлекле файдаланыла.

Утилитар стильләрдә әлеге фигыльнең кулланылуы, матур әдәбият әсәрләре белән чагыштырганда, шактый сирәк күзәтелә.

### 5.6.2. Затланышсыз фигыль формалары

Гасырлар дәвамында иске татар әдәби теленең табигатен, аның үсеш закончалыкларын билгеләгән язма традицияләр, норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык [Бәширова, 2008, б. 6] затланышсыз фигыль формаларының кулланылышында да күзәтелә. Язма чыганаклардан күренгәнчә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби телендә аларның прадигматик һәм синтагматик мәгънәләре кыпчак һәм угыз телләренә хас булган әдәби норма күрсәткечләре белән билгеләнә.

Мәгълүм булганча, затланышсыз фигыльләр исеме астында сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль һәм инфинитив формалары карала. Аларның төп үзенчәлеге буларак зат-сан белән төрләнмәүләре күрсәтелә. Семантик, морфологик һәм синтаксик планда алар үзләрендә, фигыль белән бергә, башка сүз төркемнәренең дә (сыйфат, рәвеш) билгеләрен берләштерәләр.

Бүгенге көндә төрки һәм татар тел белемендә затланышсыз фигыльләр, аларның килеп чыгышы, мәгънә, структур һәм функциональ үзенчәлекләре төрки телләр нигезендә Н.А. Баскаков (1940, 1952), Н.К. Дмитриев (1940, 1948, 1960), Н.П. Дыренкова (1940, 1941, 1948), А.Н. Кононов (1956, 1960), Ә.Н. Нәҗип (1960), К.М. Мусаев (1964), Н.З. Гаджиева (1973), В.Г. Гузев (1979), Э.А. Грунина (1991); хәзерге татар әдәби теле нигезендә Д.Г. Тумашева (1978), В.Н. Хангилдин (1959), Ф.М. Хисамова (2006); татар теленең диалектлары нигезендә Д.Г. Тумашева (1961, 1977), Г.Х. Әхәтов (1963, 1979, 1980), Л.Т. Мәхмүтова (1978), Ф.Й. Йосыпов (1985, 2004); борынгы һәм иске төрки, татар язма чыганаклары нигезендә А.М. Щербак (1962), В.М. Насилов (1963, 1974), Ә.Н. Нәҗип (1965, 1975), Я.С. Әхмәтгалиева (1979), А.Н. Кононов (1980), Л. Җәләй (2000), Х.Р. Курбатов (1971), В.Х. Хаков (1972, 1993), Ф.С. Хәкимҗанов (1978, 1987), З.А. Хисамиева (1980), Ф.С. Фәсиев (1981), Ф.М. Хисамова (1981, 1990, 1999), М.М. Нигъмәтуллов (1983), Р.З. Мөхәммәтрәхимова (1990), Г.Б. Шамарова (1990), Ф.Ш. Нуриева (1999, 2004), Ә.Р. Хәлиуллина (2002), Г.Ф. Гарипова (2003), Р.Т. Йөзмөхәммәтов (2003), Р.Ф. Мирхәев (2003), А.Ф. Йосыпов (2006), Б.К. Миңнуллин (2010) һ.б.ның хезмәтләрендә җентекле рәвештә өйрәнелгән. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби телендә затланышсыз фигыль формаларының кулланылышы белән бәйле язма традицияләр, норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-

стилистик вариантлылыкны билгеләгәндә нәкъ менә әлеге хезмәтләрдә чагылыш тапкан фикерләр фәнни-теоретик нигез итеп алынды.

*Сыйфат фигыль.* Хәзерге татар тел белемендә сыйфат фигыль исеме астында үзендә фигыль һәм сыйфатларга хас үзенчәлекләрне берләштергән, субъект, объект яисә предметның билгеле бер процесс белән бәйле билгесен ачыклап килгән затланышсыз фигыль формалары карала.

Фигыль формасы буларак сыйфат фигыль семантик планда аерым вакыт яссылыгында башкарыла торган эш-хәрәкәт мәгънәсен саклый. Ягъни аңа заман мәгънәсен белдерү хас. Сөйләм барышында әлеге мәгънә җөмләдә затланышлы фигыль формасының заманы белән конкретлаштырыла. Морфологик яктан сыйфат фигыльләр башка фигыльләр кебек, юклык һәм юнәлеш кушымчалары белән төрләнәләр. Моннан тыш, сөйләмдә алар синтетик һәм аналитик юл белән эшнең үтәлү дәрәҗәсен белдереп килә алалар, кайбер ярдәмче фигыльләр белән бергә перифрастик конструкцияләрне төзүдә катнашалар. Зат кушымчалары белән төрләнмәү сәбәпле, сыйфат фигыльләрдән аңлашылган эш-хәрәкәтнең кайсы затка каравы зат алмашлыклары һәм субъект мәгънәсен белдергән сүзләр, ә кайбер сыйфат фигыльләрдә тартым кушымчалары ярдәмендә белдерелә.

Сөйләм барышында сыйфат фигыльләр исемләшеп, үзләре белдергән эш-хәрәкәтнең субъектын яисә объектын атап киләләр һәм исем сүз төркеменә хас булган сан, тартым һәм килеш категорияләренең кушымчаларын алалар. Моннан тыш, татар телендә сыйфат фигыльләр еш кына исем фигыль мәгънәсендә кулланылалар. Бу очракта да алар исем сүз төркеменә хас морфологик күрсәткечләр белән төрләнәләр.

Бүгенге көндә татар теле диалектларында сыйфат фигыльнең егерме бер формасы кулланыла [Юсупов, 2004, с. 19–122]. Хәзерге әдәби телдә аның түбәндәге формалары норма буларак аерып чыгарыла:

1) *-учы, -а торган* кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыльләре;

2) *-р, -ачак, -асы* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыльләре;

3) *-ган* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыле [Татарская грамматика, 1997, с. 201–223; Тумашева, 1978, б. 138–147; Хисамова, 2006, б. 226–256].

Сыйфат фигыльнең хәзерге татар әдәби телендә норма буларак кабул ителгән формаларының (*-асы* кушымчалы киләчәк заман сыйфат

фигыленнән башка) төрле дәрәҗәдә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби телендә дә кулланылуы күзәтелә. Шуның белән бергә бу чорга караган иске татар язма текстларының тел тукымасын угыз телләре үзенчәлекләре саналган *-ан, -мыш* һәм *-дық* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләре дә тәшкил итә.

*-учы (-уҗсы) кушымчалы сыйфат фигыльләр.* Хәзерге татар әдәби телендә *-учы* кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыльләре, башлыча, атрибутив позициядә, ягъни сыйфат фигыльнең үз мәгънәсендә генә кулланылып, субъект, ә төшем юнәлешендә кулланылган очракта объект мәгънәсен белдергән сүзләрне ачыклап киләләр. Күпчелек очракта алар субъект яисә объектның гомуми билгесенә әверелгән заманга мөнәсәбәтсез процессны белдерә. Шул ук вакытта җөмләдәге төп фигыльгә мөнәсәбәттә аның белән бер үк вакытта һәм аннан алда башкарылган эш-хәрәкәтне дә белдереп килә алалар [Татарская грамматика, 1997, с. 220–221, Тумашева, 1978, б. 138, Хисамова, 2006, б. 253].

*-учы (-уҗсы)* кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыльләре XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтче язучыларыннан күбесенчә Р. Фәхретдиннең әсәрләрендә һәм Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә очрый. Башка авторлар тарафыннан алар сирәк кулланыла. Мисаллардан күренгәнчә, әлеге сыйфат фигыльләр фигыль нигезенә *-учы/-үче* (-وچی) кушымчасы ялганып ясала: мәктүб язучы (یازوچی) қыз [Бигиев, 1887, б. 22], қачучы (قاچوچی) арестантлар [Бигиев, 1890, б. 70], бүлмәйе буйаучы (بویاوچی) буйақчылар [Бигиев, 1890, б. 71], романы тәэлиф идүче (تألیف ایدوچی) автор [Бигиев, 1890, б. 72], хәйран улып йөрүче (یوروچی) шәкертләрнең [7, 6], бидғәтдән қурқучы (قورقوچی) затлар [Фәхретдин, 1899, б. 48], хөкем идүче (حکم ایدوچی) зат [Фәхретдин, 1899, б. 59], ғақыл вә киңәш вирүче (عقل و کیڭاش ویروچی), күңелләрене шатландыручы (شادلندروچی), серләрене һәм мөхкәм сақлаучы (ساقلاوچی) ибдәш [Фәхретдин, 1899, б. 68], сүз почтасы йөртүче (یورتوچی), төкереге илә биздерүче (بیزدروچی) йәки сәүдерүче (سودروچی) қартчықларға [Фәхретдин, 1899, б. 69], адәм ите ашаб тереклек идүче (ترکلیك ایدوچی) Африка wәхшиләре [Фәхретдин, 1899, б. 72], идарә идүче (اداره ایدوچی) ибдәшләр [Фәхретдин, 1903, б. 14], йул күстәрүб торучы (طوروچی) дүрт ишәк [Фәхретдин, 1903, б. 17], исерткеч эчүче (اچوچی) тәрҗеманым [Фәхретдин, 1903, б. 23], йир сатучы (یر صاتوچی) башқортлара [Фәхретдин, 1903, б. 64], белүче (بیلوچی) қартларымыз [Фәхретдин,

1903, б. 81], дәфтәр тотучы (توتوچى) кятибәләр [Фәхретдин, 1903, б. 88] һ.б.

Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә бу сыйфат фигыльләрнең *-ужҗы/-үжҗе* (-وجى) кушымчасы белән ясалган вариантлары кулланыла, ягъни биредә графофонетик вариантлылык күзәтелә: көлдерүҗе (كولديريجى) хикәйәләр [Кәрими, 1902, б. 79], белүҗе (بيلوجى) остазбикәләремез [Кәрими, 1902, б. 144], торужҗы (طوروجى) мөселманлар [Кәрими, 1908, б. 10], тиҗарәт идүҗе (تجارت ايدوجى) Габдессаттар Маннавов, сәүдә идүҗе (سودا ايدوجى) Сөнгатулла Хәлфийев [Кәрими, 1908, б. 11], тәрвиҗ идүҗе (ترويج ايدوجى) рүсаи руханилар [Кәрими, 1908, б. 22], буфет тотужҗы (بوفيت طوتوجى) бер чуқ қасыймлылар [Кәрими, 1908, б. 26], мөсафирханә тотужҗы (مسافرخانه طوتوجى) Қасыйм мөселманлары [Кәрими, 1908, б. 26], пайтәхетдә торужҗы (طوروجى) вә мәдәнийәт ғаләмендә йәшәүҗе (يشاوجى) мөселманлардан [Кәрими, 1908, б. 28], Қырымда йәшәүҗе (يشاوجى) халықлар [Кәрими, 1908, б. 33], ачқычларыны сақлаужҗы (صاقلاوجى) адәм [Кәрими, 1908, б. 64], атлар хәзер идүб торужҗы (حاضر ايدوب طوروجى) адәмләр [Кәрими, 1908, б. 100] һ.б.

Моннан тыш, М. Акьегетнең «Хисаметдин менла» романында аның борынгы төрки *-гучы* (-غوچى) кушымчасы белән ясалган формасы да теркәлде: Җандан сезә ғашыйқа улып қалғучы (قالغوچى) Хәнифә [Акъегет, 1886, б. 37].

Р. Фәхретдиннең әсәрләрендә *-учы (-ужҗы)* кушымчалы сыйфат фигыльләр нигездә автор сөйләмендә, публицистик чигенешләрдә кулланылалар. Атрибутив позициядә алар субъект мәгънәсен белдерә торган сүзләрнең даими билгесенә әверелгән һәм нинди дә булса заманга бәйле булмаган процессны белдереп киләләр: Тәрбийәле қызлар хатын улдықлары соңында бер өйне ғақыл илә идарә қылырлар, баланы гүзәл тәрбийә идәрләр, ирләренә ышанычлы вә туғры ғақыл вә киңәш вирүче (عقل و كيڭاش ويروچى), күңелләрене шатландыручы (شادلندروچى), серләрене һәм мөхкәм сақлаучы (ساقلاوچى) ибдәш улырлар [Фәхретдин, 1899, б. 68]; Әмма тәрбийәсез хатын, ... берне ике өлеш идүб күрше хатынларына, қулларына тәсбих тотып сүз почтасы йөртүче (يورتوچى), төкереге илә биздерүче (بيزدروچى) йәки сәүдерүче (سودروچى) қартчықларға бәйән идәрләр [Фәхретдин, 1899, б. 69]; Аллаһы тәғаләнең исемене дә белмәй адәм ите ашаб тереклек идүче (تركليك ايدوچى) Африка wәхшиләре арасында үзләренең ғореф-ғәдәтләре, әдәб дийә иғътиқад

иделгән нәрсәләре хикәйәт иделдеге хәлдә,... [Фәхретдин, 1899, б. 72] һ.б.

Аерым очракларда автор атрибутив позициядә килгән *-учы (-уҗы)* кушымчалы сыйфат фигыльләрне җөмләдәге төп фигыль белән бер вакытта башкарыла торган эш-хәрәкәтне белдерү өчен дә куллана: Сез буйақчылармы сөале қачучы (قاچوچى) арестантларны туқтатды [Бигиев, 1890, б. 70]; Үз ғыйлемләренә хәйран улып йөрүче (يوروچى) шәкертләрнең һичберендән ким дәрәҗәдә дәгел идегем илә хөкем идә идем [Фәхретдин, 1899, б. 6]; Йир сатучы (صاتوچى) башқортлара алучы табдығы кеби, йир алучы (آلوچى) нимсәләрә, латышлара, хохоллара һәм сатучы (صاتوچى) табар [Фәхретдин, 1899, б. 64] һ.б.

Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә *-учы (-уҗы)* кушымчалы сыйфат фигыльләр шулай ук автор сөйләмендә генә очрый. Атрибутив позициядә алар субъект мәгънәсен белдерә торган сүзләрнең даими билгесенә әверелгән һәм нинди дә булса заманга бәйле булмаган процессны белдерү өчен кулланылалар: Көлдерүҗе (كولديريجى) хикәйәләр сөйлийурлар [Кәрими, 1902, б. 79]; Петербург, Москва, Варшава йулларында вә саир тарафларда буфет тотуҗы (بوفيت طوتوجى) бер чуқ қасыймлылар вардыр [Кәрими, 1908, б. 26]; Бүгенге көндә Қырымда йәшәүҗе (يشاوجى) халықлар: руслар, татарлар, румлар, әрмәниләр, болғарлар, чехлар, нимсәләр, поляклар, яһүдиләр, қараимләр, қырымчақлар вә ченгәнәләр (чегәнләр)дер [Кәрими, 1908, б. 33] һ.б.

Исемләшкән очракта *-учы (-уҗы)* кушымчалы сыйфат фигыльләр үзләре белдергән эш-хәрәкәтнең башкаручысын атап киләләр һәм исем сүз төркеменә хас грамматик категорияләрнең (сан, тартым, килеш) күрсәткечләре белән төрләнәләр. Язма чыганакларда исемләшкән *-учы (-уҗы)* кушымчалы сыйфат фигыльләр үзләре белдергән эш-хәрәкәтнең субъектын атап, түбәндәге рәвештә кулланылалар:

1) баш килештә: Килүчеләр (كلوچيلر) политсә илә судебный следователь иде [Бигиев, 1887, б. 4]; Мәмәт, Ғабделғафур вә Ибраһимның ... күпме хәүф қылдықларыны бу сатралары уқучы (اوقوچى) кәндесе тасаушыр вә тәфәккер қылып белсен [Бигиев, 1890, б. 68]; Арабадан төшеп, мәзарә кәтдемегез урам сәдақа алучылар (آلوچيلار) илә тулы иде [Бигиев, 1908, б. 83]; Биңләрҗә франк қазануҗылар (قزانوجيلر) вар [Кәрими, 1902, б. 141]; Бунларың шишлық вә бузалары ғайәт әғлә улдығындан кирәк мөселмандан вә кирәк руслардан вә хосусан кибарларындан бу ашханәйә махыз шу шишлық илә буза ичүн дәвам идүҗеләр (دوام ايدوجيلر) пәк чуқдыр [Кәрими, 1908,

б. 52]; Русча, төркичә җөмләңез йахшы белдегеңез кеби, араңызда аз улса да франсыз, нимсә, ғарәб, фарсы делләрене белүчеләр (بيلوچيلر) һәм вардыр [Фәхретдин, 1899, б. 13]; Сәфохәт ахыры нидәмәт (үкенеч) идеге, фетнәгә ут салучылар (اوت سالوچيلر) үзләре һәм бергә йанып көл улдығы, һәр көн күрелүб торылмақдадыр... [Фәхретдин, 1899, б. 74]; Ғайеб кенә дәгел, хәтта ғайбәт идүчеләр (غيبت ايدوچيلر) улыр [Фәхретдин, 1903, б. 25]; Бәлки буны белүчеләр (بيلوچيلر), хәтта ки алып вирүчеләр (آلوب ويروچيلر) бәлки ошбу поездда һәм вардыр... [Фәхретдин, 1903, б. 61] һ.б.;

2) иялек килешендә: Бән исә аз белүчеләр сүзендән дәгел, үзләрене беренче ғалим дийә иғтиқад идүчеләрнең (اعتقاد ايدوچيلرنڭ) бу ысулы җәдидне инкяр идүб сүзләгән җөмләләрендән бер шәй аңламаз идем [Фәхретдин, 1899, б. 44]; Бишекдә улан сабый балалар, тибрәтүчеләрең (تبراتوچيلرك) моңлы давышларындан ләззәт алып уйурлар [Фәхретдин, 1903, б. 22]; Сәлим бабайның Хива сәфәрене, қырғызларың ғореф вә ғәдәтләрене, туй тамашаларыны ривайәт итдеге wақытында дыңлаучыларың (دكلاوچيلرك) ағызларындан сулар ағар иде [Фәхретдин, 1903, б. 23] һ.б.;

3) юнәлеш килешендә: Ата вә бабалар йулындан чықмай искечә торучыларға (توروچيلرگا) афәрин... [Фәхретдин, 1899, б. 61]; Бундан башқа йорт хезмәтләре күб, сабан сөрүчеләргә (سوروچيلركه) икмәк пешерергә кирәк, қамыр баса белүб булмай!... [Фәхретдин, 1903, б. 106] һ.б.;

в) төшем килешендә: Халықға хезмәт идүчене (خدمت ايدوچينى) падишаһ һәм йаратадыр [Фәхретдин, 1899, б. 24]; Бу хәлдә үзләрене ғақыллы адәм уғлы, хосусан мөселман дийә иғтиқад иткән кемсәнәләрдән, дөнйада иң зәғиф күрелгән хатынлар таифәсене аздырып-туздырып, күңелләрене саташдырып, юлларыны адашдырып йөреп тә, соңра һәрбер ғайеб вә қабәхатне хатынларға йабып йөрүчеләрне (يوروچيلرنى) қызғана идем [Фәхретдин, 1899, б. 73]; Ғаббас мелла бу қарйайа күрә Дамустин улып, сөйләргә маһирлеге сәбәбендән дыңлаучылары (دڭلاوچيلرى) эстәсә көлдерә, эстәсә ағлата белер иде [Фәхретдин, 1903, б. 6]; Йаучы суғыш идүче мәғнәсендә улып, илк заманларда қызлары күб wақытда көчләб суғышып алдықларындан қыз сораучыны (قز صوروچينى) бу көнә қәдәр йаучы димешләр [Фәхретдин, 1903, б. 18] һ.б.;

4) чыгыш килешендә: Һәр wақытта хатынларны риғайә идәргә вә анларға йәрдәм вә мәрхәмәт қылырға тийешле, дийү мәғлүмат вирүче,

вәгъәз һәм нәсихәт қылучылардан (نصيحت قيلوچيلردن) һичберсе, бу зәгыйфь мәхлуқларға үз урынларыны исар итмәзләр иде... [Фәхретдин, 1899, б. 16]; Күбесе урамда деләнчелек идүб йөрүчедән (يوروچيدن) ғибәрәт улған қыз балалар иман, иғтиқад вә ғилме хәл белгәнләр, вә бундан өстен нәқыш вә чигеш кеби қул һөнәре үгрәнгәнләр, имде ул балаларға ризық ишеге ачылған [Фәхретдин, 1899, б. 45]; Кем дә кем бу доғаны йылында бер кәррә улсын уқымаз, үзе уқый белмәдегендә белүчедән (بيلوچيدن) уқытмаз исә... [Фәхретдин, 1903, б. 69]; Ләкин уғлының ғилме йахшы идегене күб кемсәләрдән вә белүчеләрдән (بيلوچيلردن) ишетмеш идем [Фәхретдин, 1903, б. 79] һ.б.;

5) урын-вакыт килешендә: Дөнйада сәүдермәк яки биздермәк, бозмақ, вар дийә иғтиқад идүчеләрдә (اعتقاد ايدوچيلرده) күрелгән йө*рәксезлек буңа дөрест шаһид ула белер [Фәхретдин, 1899, б. 9].*

*-учы (-ужҫы)* кушымчалы сыйфат фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең барысы өчен дә хас түгел. Алар нигездә Р. Фәхретдин әсәрләренең публицистик катламында атрибутив һәм субстантив позициядә теркәлде. Ф. Кәрими сәяхәтнамәләрендә бу сыйфат фигыльләрнең *-ужҫы* кушымчалы вариантлары кулланыла. З. Бигиев романнарында алар субстантив позициядә генә очрыйлар. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романы өчен *-учы (-ужҫы)* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең кулланылуы бөтенләй хас түгел.

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-учы (-ужҫы*) кушымчалы сыйфат фигыльләр ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда һәм газета текстларында очрыйлар [Шамарова, 1990, с 77; Миннуллин, 2012, с. 190–191]. Аерым кулланылыш очраклары дини-фәлсәфи хезмәтләрдә теркәлгән [Абдулхаков, 2007, с. 21]. Шигъри әсәрләр теле өчен алар хас түгел. Нәтиҗә ясап әйткәндә, *-учы (-ужҫы)* кушымчалы сыйфат фигыльләр бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алмыйлар һәм функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләр. Хәзерге татар әдәби телендә *-а торган* кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыльләр күбрәк атрибутив позициядә кулланылалар һәм эш-хәрәкәтнең субъектын, объектын, урынын, вакытын белдергән һәм корал мәгънәсендәге сүзләрне ачыклап киләләр. Алар, нигездә, субъект яисә объектның гомуми билгесенә әверелгән заманга мөнәсәбәтсез процессны белде-

рәләр. Чагыштырмача сирәк очракларда *-а торған* кушымчалы сыйфат фигыльләр үзләре ачыклап килгән сүзләрне сөйләү моменты белән бер вакыт яссылыгында башкарылган, ягъни хәзерге заманга караган эш-хәрәкәт буенча характерлыйлар [Татарская грамматика, 1997, с. 222; Тумашева, 1978, б. 140; Хисамова, 2006, б. 255].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-а торған* кушымчалы сыйфат фигыльләр М. Акъегет һәм З. Бигиев романнарында гына очрыйлар. Биредә дә алар сирәк кулланылалар. Язучылар бу затланышсыз фигыльләргә нигездә пейзаж күренешләрен һәм персонажларның портретларын тасвирлаганда мөрәҗәгать итәләр. Публицистик чигенешләрдә алар теркәлмәде.

Мисаллардан күренгәнчә, *-а торған* кушымчалы сыйфат фигыльләр фигыль нигезенә *-а/-ә* (ا-/ه-), *-ый/-и* (ى-) кушымчасы һәм торған (طورغان) ярдәмче фигыле ялганып ясалалар: адәмне бақтыра торған (باقتوره تورغان) қыйәфәт [Акъегет, 1886, б. 43], детри торған (دترى طرغان) таwыш [Бигиев, 1887, б. 67], сорны тәрәзәдән ташлый торған (طاشلى طورغان) ғәдәт [Бигиев, 1887, б. 42], ат уғрысыны хәбес қыла торған (حبس قيلا طورغان) бүлмә [Бигиев, 1887, б. 34], мәғйүбләр ултыра торған (اولتوره طرغان) йир [Бигиев, 1887, б. 40], үзем тора торған (تورا تورغان) бүлмәләр [Бигиев, 1890, б. 71],

Өйрәнелгән текстларда *-а торған* кушымчалы сыйфат фигыльләр нигездә эш-хәрәкәтнең субъекты (а), объекты (ә) һәм башқарылу урыны (б) мәгънәсендәге сүзләр белән бергә кулланылалар һәм эш-хәрәкәтне аларга гомумән хас булган билге итеп белдерәләр:

а) Сәлимгәрәй хәзрәтләренең йөзе адәмне бақтыра торған (باقتوره تورغان), тарта торған (تارته تورغان) вә әмнийәт чықарта (امنيت چقارته) торған қыйафәт иде [Акъегет, 1886, б. 43]; Детри торған (دترى طرغان) таwыш илә «Зөләйха, Зөләйха» дийү тәкрар қылып ... йығламаға башлады [Бигиев, 1887, б. 67];

ә) Сезнең хадимеңез нумерәңездән сорны җыйып туғры тәрәзәдән ташлый торған (طاشلى طورغان) ғәдәте йуқмы иде [Бигиев, 1887, б. 42];

б) Муса әфәнде йалғыз бер бүлмәйә мәхбүс улып, бу бүлмәсе дә ат уғрысыны хәбес қыла торған (حبس قيلا طورغان) бүлмә кеби кечеқ қараңғы вә пычрақ вә суық улмайынча, бер бүйүк бүлмә иде [Бигиев, 1887, б. 34]; Аның артындан ике солдат арасында Муса Салихов керүб мәғйүбләр ултыра торған (اولتوره طرغان) йиргә барып ултырды [Бигиев, 1887, б. 40]; Менә минем үзем тора торған (تورا تورغان) бүлмәләрдә тәрәзәләрне буйарға кирәк... [Бигиев, 1890, б. 71].

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләр ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда һәм газета текстларында очрыйлар [Шамарова, 1990, с. 77; Миннуллин, 2012, с. 190–191]. Башка язма чыганаклар өчен алар хас түгел. Нәтиҗә ясап әйткәндә, *-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләр бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алмыйлар һәм функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар. Бу аларның әдәби кулланылышка яңа керә башлавы һәм мәгънәләренең язма текстларда башка затланышсыз фигыльләр тарафыннан белдерелүе белән аңлатыла.

*-р* кушымчалы сыйфат фигыльләр. Хәзерге татар әдәби телендә *-р* кушымчалы сыйфат фигыльләр төрле мәгънәдәге (субъект, объект, урын, вакыт) сүзләр белән кулланылалар һәм аларны нинди дә булса заманга мөнәсәбәтсез даими башкарыла торган яисә киләчәктә булачак эш-хәрәкәт буенча ачыклап киләләр [Татарская грамматика, 1997, с. 212–213; Тумашева, 1978, б. 144; Хисамова, 2006, б. 242].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-р* кушымчалы сыйфат фигыльләр нигездә автор сөйләмендә, пейзаж тасвирламаларында һәм публицистик чигенешләрдә кулланылалар. Аерым очракларда Язучылар әлеге сыйфат фигыльләрне персонажлар сөйләменә дә кертеп җибәрәләр.

М. Акьегетнең «Хисаметдин менла» романында *-р* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең *кеби* (كبى) бәйлеге белән бергә кулланылу очрагы гына теркәлде. Автор әлеге *-р кеби* конструкциясен җөмләдәге башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен тасвирлау максатыннан файдалана: Вә берничә дакикадан соңра халқа белдермәйеп, гүйә үз эшенә кидәр кеби (كيدر كبى) мөсафирханәдән чықды [Акъегет, 1886, б. 20].

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында һәм «Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» сәхәтнамәсендә *-р* кушымчалы сыйфат фигыльләр атрибутив позициядә генә кулланылалар. Мисаллардан күренгәнчә, алар сыйфатланмышларын нинди дә булса заманга мөнәсәбәтсез даими башкарыла торган эш-хәрәкәт буенча ачыклап, *-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләрне алыштырып киләләр: Хәзердә һич бер қайдан да ақча алыр (آلور) җирем йуқ [Бигиев, 1890, б. 12]; Ғабделғафурның мәдрәсәдә урнысы дәрес әйтеләчәк урында улдығы ичүн һәр көн дамелла дәрескә керер (كرر) wақытда ғына эчийур иде [Бигиев, 1890, б. 50]; Соғыд мәмләкәтендә Зәрафшан

әтрафында иқамәт идәр (اقامت ايدر) қаwемләр иске wақытларда ғайәт мөнтазам дәүләт тәшкил идеп, падишаһлары иң әүwәл Бикенд, Чимкенд нам шәһәрләрдә қәрар идәрләр имеш [Бигиев, 1908, б. 3]; Безем милләтемез кеби утанмаз (اوتانماز), ойалмаз (اويالماز) бер милләт, ғөман идәрем, һичбер йирдә йуқдыр [Бигиев, 1908, б. 33]; Уқыр-йазар (اوقور يازار) хатын Бохарада һич булынмайур имеш [Бигиев, 1908, б. 71] һ.б.

Аерым очракларда автор *-р* кушымчалы сыйфат фигыльләрне *-ган* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләре урынында да куллана: Учитель Әхмәрский фәрманы уқып тәмам идәр (تمام ايدر) wақытда ив хуҗасы Ғалийевләрнең прикашчигы килеп... [Бигиев, 1890, б. 13]; Қазандан кидәр (كيدر) сәғәтдә генә ишетдем... [Бигиев, 1890, б. 37].

«Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» сәяхәтнамәсендә язучы юклык формасындагы *-р* кушымчалы сыйфат фигыльләрне *дәрәҗәдә* сүзе белән бергә башка эш-хәрәкәтнең, яисә затка, предметка, күренешкә хас сыйфат-билгеләрнең дәрәҗәсен тасвирлау максатыннан да файдалана: У заманың ғолүменә, мәғәрифенә мәркәз улан Бохара, Сәмәрқанд әүwәлге хәленә ғәүдәт идәмәмәз (عودت ايده مز) бер дәрәҗәйә инде [Бигиев, 1908, б. 7]; Атәш эчендә қалмыш имам әфәнде, хатыны, өч сабый балалары, қалебләр дайанмаз (طايانماز) дәрәҗәдә ачы-ачы ағлайып-бағырып, ханә илә бәрабәр йандылар! [Бигиев, 1908, б. 20]; Әмирләрең, бөйекләрең, ғалимләрең шу ике хосусда мөсаһәләләре ғафу қылынмаз (عفو قيلنماز) дәрәҗәдә бөек қосурдыр [Бигиев, 1908, б. 67] һ.б.

Моннан тыш, сәяхәтнамәдә *-р* кушымчаларны сыйфат фигыльләрнең инфинитив урынында кулланылу очраклары да теркәлде: Мөсафирләр рәхәт асайыш илә шимди бураларда хәрәкәт идәр (حركت ايدر) улдылар [Бигиев, 1908, б. 47–48]; Төрекмәнләр һәмәнһәмишә Чат шәһәренә, әхйанән Чикишләрә һөҗүм идәр (هجوم ايدر) улдылар [Бигиев, 1908, б. 52–53].

Р. Фәхретдин әсәрләрендә *-р* кушымчалы сыйфат фигыльләр атрибутив функциядә һәм *ичүн* (ايچون), *қәдәр* (قدر), *кеби* (كبى) бәйлекләре белән бергә төрле конструкцияләр составында кулланылалар. Атрибутив позициядә автор аларны сыйфатланмышка гомумән хас булган билгене тасвирлаганда куллана: Мәғнәсез сүзләре илә башымны ағыртуындан хәлас улырым (خلاص اولورم) нийәте илә сүзене рәд итмәз идем [Фәхретдин, 1899, б. 44]; Бунық йөзене қызартмақны,

йәки қаралтмақны ғафу улынмаз (عفو اولنماز) бер ғайеб хисаб идә идем [Фәхретдин, 1899, б. 72] һ.б.

Моннан тыш, автор *-р* кушымчалы фигыльләрне *дәрәҗәдә* (درجه ده) сүзе белән бергә башка эш-хәрәкәткә, яисә зат, предмет, күренешкә хас сыйфат-билгеләрнең дәрәҗәсен (а), *рәвешдә* (روشده) сүзе белән бергә башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен (ә) тасвирлау өчен куллана:

а) «Тәрҗеман» исә бу бабда дөнйа тәхмил итмәз дәрәҗәдә (تحمل ايتماز درجه ده) мөшкелләрне йөкләб мәсләгендә сабит улмышдыр [Фәхретдин, 1899, б. 76]; Қыйраәтханәдә дөнйамны онытыр дәрәҗәсендә (اونتور درجه سنده) мәхәббәт илә wақыт уздырыр идем [Фәхретдин, 1899, б. 76]; Бу исә тәғриф иделмәз дәрәҗәдә (تعريف ايدلماز درجه ده) бүйүк бер сәғәдәтдер [Фәхретдин, 1899, б. 80];

ә) Вә буны тайид ичүн ачуланмаз вә қыздырмаз рәвешдә (آچولندرماز و قزدرماز روشده) шиғыйлар хосусында йәшдән бирле ишетдегем сүзләрне, золем вә тәғассыбларны, хәтеремдә қалған микдарынча хикәйәт итдем [Фәхретдин, 1899, б. 51–52].

Р. Фәхретдин әсәрләрендә башка эш-хәрәкәтнең үтәлү сәбәбен һәм максатын күрсәтү өчен *-р ичүн* конструкциясе кулланыла: Вә бәғзеләре исә беләзек эчендә улған қулларны, эшләпә астындағы матур қашларны, алтын кеби сары сачларны, күзләр илә йөзләрне күзләр ичүн (كوزلر ايچون) килмешләр иде [Фәхретдин, 1899, б. 15]; Шуның ичүн бу музыка даwышыны дыңлар ичүн (دڭلار ايچون) ашығып вардым, ханымлар һәм бәндән қалмадылар [Фәхретдин, 1899, б. 39]; Бере, ахшам намазыны уқыр ичүн (اوقور ايچون) шәм эзләтүб, намаз wақытыны уздырмыш иде [Фәхретдин, 1903, б. 27]; Ундүрт-унбиш йәшләрендә булыр, бер бала яныма килеп сәлам вирде, бән дә сикереп тордым да, күрешер ичүн (كورشور ايچون) қулымы суздым [Фәхретдин, 1903, б. 84] һ.б.

*-р қәдәр* конструкциясен автор персонажга хас нинди дә булса сыйфатның дәрәҗәсен күрсәтү өчен файдалана: Чөнки сүзләшер қәдәр (سوزلشور قدر) русчаны бән белмидер идем [Фәхретдин, 1899, б. 19].

*-р кеби* конструкциясе башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен тасвирлаганда кулланыла: Бунлар гүя қаты қычқырышмақ мөсабәқасы (ярышмақ) идәр кеби (مسابقه سى (يارشمق) ايدر كبى) бер-берендән артық қычқырышырлар [Фәхретдин, 1903, б. 59].

Ф. Кәрими сәяхәтнамәләрендә *-р* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең бары тик аерым кулланылыш очраклары гына теркәлде:

Французларың зийадәсе илә фәғәл бер тарзда сабит қалмайып, хәлдән-хәлгә инқыйлабы сәвәр (سوه ر) бер милләтдер [Кәрими, 1902, б. 105]; Иштә ике мөнтәһанең арасында бер тақым локанталар вардыр ки, әсәсләренең зиннәт вә мөкәммәлияте мәтбуқатының нәзафәт вә нәфәсат җәһәте илә мәзан дурәләрә дәгешелмәз (دكيشلمز) фийатлары да өч франқ илә биш франқ арасындадыр [Фәхретдин, 1903, б. 134].

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-р* кушымчалы сыйфат фигыльләр ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда, шигъри әсәрләрдә, газета текстларында һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә кулланылалар [Шамарова, 1990, с. 78; Юсупов, 2006, с. 115; Миннуллин, 2012, с. 198–199; Абдулхаков, 2007, с. 21]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норманың бер күрсәткече булып торалар.

*-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләр. Хәзерге татар әдәби телендә *-ачақ* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыльләр атрибутив позициядә төрле мәгънәдәге (субъект, объект, урын, вакыт) сүзләр белән кулланылалар һәм аларны киләчәктә башкарылачак эш-хәрәкәт буенча ачыклап киләләр. Билгеле бер контекстта алар сыйфатланмышларыннан башка һәм исем фигыль буларак та кулланыла алалар [Татарская грамматика, 1997, с. 219–220; Тумашева, 1978, б. 145–146; Хисамова, 2006, б. 250–251].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләр күбесенчә автор сөйләмендә кулланылалар. Алар фигыль нигезенә *-ачақ/-әчәк* (-ه چق/-ه چك) һәм *-аҗақ/-әҗәк* (-ه جق/-ه جك) кушымчалары ялганып ясалалар: диққәт олунаҗақ (اولنه جق شى) шәй [Акъегет, 1886, б. 15], аңлашылачақ (آنكلاشلاچق) эш [Бигиев, 1887, б. 4], әйтеләчәк (آيتلاچق) сүз [Бигиев, 1887, б. 15], қул қуйылачақ (قول قويلاچق) йирдә [Бигиев, 1887, б. 31], бәйан идәчәгемез (بيان ايده چكمز) Ғабделғафур [Бигиев, 1890, б. 2–3], ахун вә хатиб җәһәтләренә керәҗәк (كيرجك) адәм [Бигиев, 1890, б. 13], мәнем әйтәчәк (آيتاجق) сүзләр [Бигиев, 1890, б. 31], төрле йақдан ишеделенәчәк (ايشدلنه چك) қурай даwышларыны [Фәхретдин, 1899, б. 8], сәбәб улачақ (اوله چق) ғыйлем вә мәғрифәт әһелләрене [Фәхретдин, 1899, б. 10], халқымызның алға варачақ (واره چق) йулларыны [Фәхретдин, 1899, б. 13], өч йылда уқылачақ (اوقوله چق) дәресләр [Фәхретдин, 1903, б. 8], күңел ичүн рәхәт вирәчәк

(ويرچك) шәй [Фәхретдин, 1903, б. 10], ғәдәт вә тәрбийәсене тәфтиш идәчәк (تفتيش ايده چك) урында [Фәхретдин, 1903, б. 11] һ.б.

З. Бигиев һәм Ф. Кәрими сәяхәтнәмаләрендә бу сыйфат фигыльләрнең *-аҗақ/-әҗәк* (ه- جق/ه- جك) кушымчасы белән ясалган вариантлары кулланыла, ягъни биредә графофонетик вариантлылык күзәтелә: ислам мәмләкәтләренә җасуслық сыйфаты илә кидәҗәк (كيده جك) бер адәмә [Бигиев, 1908, б. 12], инәҗәк (اينه جك) мәнзизлемез [Бигиев, 1908, б. 13], сезә дийәҗәк (ديه جك) сүзем [Бигиев, 1908, б. 24], ислах қылынаҗақ (اصلاح قيلنه جق) мәдрәсәләрең [Бигиев, 1908, б. 108], кидәҗәге (كيده جكى) юлың вә гәзәҗәге (كزه جكى) wақытың озынлығына [Кәрими, 1902, б. 2], йықанаҗақ (ييقانه جق) йирләре [Кәрими, 1902, б. 6], тамаша иделәҗәк (تماشا ايديله جك) шәйләр [Кәрими, 1902, б. 25], күңел нурландыраҗақ (نورلندره جق), фикер ачаҗақ йирләр (فكر آچه جق) [Кәрими, 1908, б. 8], Бағчасарайа киләҗәк (كله جك) милләтең зыялылары [Кәрими, 1908, б. 8], манара башына қуйылаҗақ (قويله جق) айлар [Кәрими, 1908, б. 10] һ.б.

Язма чыганакларда атрибутив позициядәге *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләр предмет яисә затны сөйләм моментыннан соң башкарылачак һәм тиешлелек модаль мәгънә төсмере белән баетылган процесс буенча ачыклап киләләр. Аерым очракларда алар үзләренә зат кушымчаларын алырга мөмкин. Сыйфатланмыш урынында бу сыйфат фигыльләрдән аңлашылган эш-хәрәкәтнең субъекты, объекты, башкарылу вакыты һәм урынын белдерүче сүзләр килә.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең атрибутив позициядә бары бер генә кулланылыш очрагы теркәлде: Ләкин Хисаметдин менла бунларың батини әфкәрләрене белмәйеп ачық илә җаwабланды ки, диккәть улынаҗақ (دقت اولنه جق) шәй йуқ [Акъегет, 1886, б. 15].

Биредә алар автор тарафыннан күбрәк исем фигыль буларак файдаланыла. Әлеге позициядә *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләр зат, килеш кушымчалары белән төрләнәләр һәм киләчәктә башкарылачак эш-хәрәкәтне атап, түбәндәге рәвештә кулланылалар:

1) төшем килешендә: Чүнкә менла иртәгә сабахда шәһәрә киләҗәгене (كله جكنى) тәхсис әйләмеш иде [Акъегет, 1886, б. 36]; Хәнифә туташ Сибғатулла әфәндейә вармайаҗағыны (وارميه جغنى) вә менла Хисаметдинә вармақ морадыны һәр нә қәдәр анасына сөйләде исә дә,... [Акъегет, 1886, б. 49]; Хәнифә туташ Хисаметдин менладан ғайрейә

яр улмайажағыны (يار اولميه جعنى) белдердеге илә Шәмсеқамәр абыстай туйны тиз қылмаға ғайрәт итде [Акъегет, 1886, б. 54–55] һ.б.;

2) чыгыш килешендә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен тасвирлаганда: Ғаббас аға вә Шәмси абыстай бүйүк вә бай адәмләр арасына керүб әкрабалық вә ыруғлық кәсеб идәжәкләрендән (كسب ايده جكلروندن) мәсрур иделәр [Акъегет, 1886, б. 36];

3) урын-вакыт килешендә башка эш-хәрәкәтнең үтәлү вакытын күрсәткәндә: Икенче көн Ғаббас аға баш қодаларның тәклифене рәд итмәйеп диде ки, икенче кәләжәгеңездә (كله جككزده) сүзне тәмамлармыз вә шу хәлдә баш қодаларны озатты [Акъегет, 1886, б. 36].

З. Бигиев әсәрләрендә *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләр нигездә атрибутив позициядә кулланыла. Автор аларга түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә:

1) предмет яисә затның киләчәктә башкарылачак эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен тасвирлаганда: Хикәйәмездән уқылып аңлашылачақ (آنكلاشلاچق) эш берничә сәнә мөқәддәм бәлдәи Қазанда wақыйғ улмыш эшдер [Бигиев, 1887, б. 4]; ...секретарьнең өстәленә хөкем wақытында зарур улачақ (ضرور اولاچق) кәғәзләрне ба тәртиб қуйадыр иде [Бигиев, 1887, б. 38]; Бүген Ғабделғафурның Қазанға кидәчәк (كيده چك) көнедер [Бигиев, 1890, б. 5]; Нә қылсын, нә тариқа Маһруй бу Сибирийәдән вә хөкем хозурында улачақ (اولاچق) мөзәлләт вә кимлекдән хәлас улсын?! [Бигиев, 1890, б. 31]; Вабур хәрәкәтендә дәвам идеп, инәжәк (اينه جك) мәнзилемез улан Қалач нам пристанә яқынлашмақда иде [Бигиев, 1908, б. 13] һ.б.;

2) предмет яисә затка гомумән хас булган процессуаль билгене күрсәткәндә: Муса әфәнденең ағызындан қайғылы wақытда әйтеләчәк (آيتلاچق) «Ах, ух» дигән сүз ишетеләдер [Бигиев, 1887, б. 15]; Шәһәрләрдә ахун вә хатиб җәһәтләренә керәжәк (كيرجك) адәм русча йазмақ вә уқымақ, хисаб қылмақ белмәсе лйаземдер [Бигиев, 1890, б. 13]; Ғабделғафурның мәдрәсәдә урнысы дәрес әйтеләчәк (درس آيتلاچك) урында улдығы ичүн һәр көн дамелла дәрескә керер wақытда ғына эчийур иде [Бигиев, 1890, б. 50] һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, икенче очракта *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләр *-а торган* хәзерге заман сыйфат фигыльләрен алыштырып киләләр.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең субстантив позициядә кулланылу очрагы да теркәлде: Аwыл вә қарйа имамлықы җәһәтенә керәчәкләр

(كيره چكلر) русча сүзләшмәйә вә уқымайа белмәләре лйаземдер [Бигиев, 1890, б. 13].

Исем фигыль урынында *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләр киләчәктә башкарылачак эш-хәрәкәтне атап киләләр. Автор аларны түбәндәге рәвештә файдалана:

1) юнәлеш килешендә: Төрекмәнләр Ғашыйқ Абадда тупланып, мөшавәрә соңында үз араларындан җәнарал Скобелев җәнабләренә ақсақаллар күндәреп, Русйайа табиғ улаҗақларына (تابع اولاجقلارينه), рәхәт һәм тыныч тораҗақларына (طوراجقلارينه) ғаһед виреп табғыйәте қабул итделәр [Бигиев, 1908, б. 55];

2) төшем килешендә: Муса әфәнде үткән көндә Андреевка баруыны һәм господин Андреевның бүген 11 сәғәтдә киләчәген (كله چكن) сөйләде [Бигиев, 1887, б. 27]; Әгәр дә Ибраһим Ғалийев бүген акушерқаның хезмәтчесен тәмам қылмаса, ... хәленең йаман улачағыны (يمان اولاچغنى) дөшенеп, ... Мәмәтнең сөаль қылдығы йазуйы Мәмәтнең тәғлиме илә йазып, кәндесе қул қуйып, Мәмәт вә Ғабделғафурдан қул қуйдырды [Бигиев, 1890, б. 54]; Зира имамларымызың қабәхәтләрене, милләтемезең қосурларыны сөйләйәҗәк исә, җаwвабдан ғаҗизлегеме, утанып қалаҗағымы (قالاجغمى) белер идем [Бигиев, 1908, б. 30–31] һ.б.;

3) чыгыш килешендә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен күрсәткәндә: Шу яңа шәһәрә, дәүләтең дийәнәтенә, мәдәнийәтенә, мәғәрифенә, сәнаиғына мәркәз қылынаҗағындан (قيلنه جغندن) гүйә, «зиннәте ходаи» мәгънәсендә улан «Быґ ара» намы вирелмеш [Бигиев, 1908, б. 3].

Аерым очракларда автор *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләрне *қәдәр* (قدر) һәм *кеби* (كبى) бәйлекләре белән бергә куллана. *-ачақ кадәр* конструкциясе персонажларның хис-кичерешләренә бәйле рәвештә аларның дәрәҗәсен тасвирлаганда файдаланыла: Хәдичә туташ да бу кеби гүзәл мәслихәтне ишедеп, тәхте қәләмдә тәмам улмайачақ қәдәр (تمام اولمياچق قدر) шадланды [Бигиев, 1887, б. 29] һ.б.

*-ачақ кеби* конструкциясе башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен күрсәтү өчен кулланыла: Романымызда мәхлуқ улан әшхасның әксәре гөнаһлы бәндәләр улып, дөнйалары башдан ахырына қәдәр хараб вә бишекдән қаберә қәдәр фәләк ғаддарында булындықлары бу wақыйғадан мәғлүм улачағы кеби (معلوم اولاچغى كبى) йәүме мәхшәрдә ғафурер рәхим аллаһының рәхмәте вә фазылына мөлақат қылмасалар, әһле җәһәннәм улдықлары аңлашылачақдыр [Бигиев, 1890, б. 2].

З. Бигиев «Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» сәяхәтнамәсендә *-ачаķ (-аҗаķ)* кушымчалы сыйфат фигыльләрне инфинитив урынында да куллана: Чәй эчәҗәк (ایچه جك) улдым [Бигиев, 1908, б. 16]; ...шу хезмәте ғаскәрийә туғрысында Ғабдуллайа беркач сүз дийәҗәк (دیه جك) улдым [Бигиев, 1908, б. 23–24]; Айука Русийәйе мөхафаза идәҗәк (محافظه ایده جك), Русийә Айуķайа баруд, аләте хәрбийә кеби бәғзе шәйләре вирәҗәк (ویره جك) улды [Бигиев, 1908, б. 34] һ.б.

Р. Фәхретдин романнарында *-ачаķ (-аҗаķ)* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең кулланылыш даирәсе, башка чыганаклар белән чагыштырганда, күпкә киңрәк. Автор күбесенчә аларны атрибутив позициядә һәм исем фигыль урынында куллана. Шуның белән бергә язучының әсәрләрендә бу сыйфат фигыльләрнең субстантив прозициядә килү очраклары да теркәлде.

*-ачаķ (-аҗаķ)* кушымчалы сыйфат фигыльләрне атрибутив позициядә язучы түбәндәге очракларда куллана:

1) предмет яисә затның киләчәктә башкарылачак эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен тасвирлаганда: Җәмғыйәтемезне алға йибәрергә сәбәб улачаķ (سبب اوله چق) ғыйлем wә мәғрифәт әһелләрене йитешдермәк сезгә лйаземдер [Фәхретдин, 1899, б. 10]; Ләкин ислам фәлсәфәсе вә серләрене аңлаб беләчәк (بیله چك) кемсәгә бик аз вә надир тәсдеф иделенер [Фәхретдин, 1899, б. 26]; Һәр нә ķәдәр бу урында хикәйәтдән бер тарафа чыķдыķ исә дә, Әсманың тереклек идәчәк (ترکللك ایدچك) урныны аңлатмаķ ķасды илә сөйләдек [Фәхретдин, 1903, б. 48]; Бәлки ķалдырмыш улыр идем, бу туғрыда йул күстәрәчәк (کوسترچك) ғалимләр вә ғаķыллы адәмләре кәндемдән биздердем [Фәхретдин, 1903, б. 106] һ.б.;.

2) *-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләр урынында предмет яисә затка гомумән хас булган процессуаль билгене күрсәткәндә: Туташ. Ķызларның үз хозурларында һәм ардларында тәғзыйм вә олуғлаб әйтеләчәк (آیتلنه چك) бер хикмәтле ләķабдыр [Фәхретдин, 1899, б. 17]; Буңа ķаршы әйтеленәчәк (آیتولنه چك) җаwабларны гүйә әүwәлдән хәзерләп ķуймыш мисалында Сәлимә туташ сүзгә керешүб бөйлә диде... [Фәхретдин, 1899, б. 52]; Ләкин ғәдәти бурычлардан улмай, дөнйа вә ахирәтдә соралыначаķ (سورالنه چق) бурычдыр [Фәхретдин, 1899, б. 65]; Балаларымыз өч йылда уķылачаķ (اوقوله چق) дәресләрне бер йылда уķысынлар [Фәхретдин, 1903, б. 8]; Күңел ичүн рәхәт вирәчәк (ویرچك) шәй гәзитәләр вә әдәби рисаләләрдер [Фәхретдин, 1903, б. 10] һ.б.

Аерым очракларда *-ачак (-аҗак)* кушымчалы сыйфат фигыльләрдән аңлашылган эш-хәрәкәт тиешлелек модаль мәгънә төсмере белән баетыла. Бу очракта алар *-асы* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыльләрен алыштырып киләләр: Мәзкүр дачада күрәчәк (کوره چك) кемсәнәм, Казанда wакытымда күп изгелегене күрдегем, Хәсән намында олуғ бер сәүдәгәр иде [Фәхретдин, 1899, б. 43]; Хәлфәләр вә күбесенчә Казандан укып килмеш шәкердләр тозуғ бабында хатын улачак кемсәнең холык вә фигылене, ғыйлем вә мәғрифәтене, ғәдәт вә тәрбийәсене тәфтиш идәчәк (تفتیش ایده چك) урында, йалғыз атасының байлығыны тикшереп, күб wакытда байғуралар кызларыны остазбикә идәрләр иде [Фәхретдин, 1903, б. 11] һ.б.

Моннан тыш автор *-ачак (-аҗак)* кушымчалы сыйфат фигыльләрне *дәрәҗәдә* (درجه ده) сүзе белән бергә башка эш-хәрәкәтнең, яисә персонажга хас сыйфат-билгеләрнең дәрәҗәсен күрсәткәндә дә куллана: ...афәрин укытдырачак (اوقتدره چق) дәрәҗәдә ғарәбчәне дөрест сүзләшә белдекләрене; ...газеталарда укыр идем [Фәхретдин, 1899, б. 20]; Каваи ноктасы вә хитабларында улан фәсахәт вә бәлағате ғакыллары хәйран идәчәк (حیران ایدچك) дәрәҗәдә улмышдыр [Фәхретдин, 1903, б. 6].

Сыйфатланмышларыннан башка *-ачак (-аҗак)* кушымчалы сыйфат фигыльләр язма чыганакларда *йук* (یوق) һәм *вар* (وار) хәбәрлек сүзләре белән бергә кулланылалар: Тордығым мәдрәсәдә йәнәдән кырык йыл торыр исәм дә сүз әйтәчәк (سوز آیته چك) йук иде [Фәхретдин, 1899, б. 6]; Моталағаңызға бер дийәчәгем (دیه چکم) йукдыр [Фәхретдин, 1899, б. 25]; Башка деләнчеләр һәркемең ардындан, гүйә алачаклары (آلاچقلری) вар кеби сораб йөрдекләрендә, бу кыз туктамыш урынында гүйә җансыз нәрсә вә йә күләгә мисалында, һич тибрәнмәй вә кузғалмай торыр иде [Фәхретдин, 1903, б. 63].

Исем фигыль урынында *-ачак (-аҗак)* кушымчалы сыйфат фигыльләр киләчәктә башкарылачак эш-хәрәкәтне атап киләләр. Автор аларны түбәндәге рәвештә файдалана:

1) баш килештә: Халык ичүн бу кеби кайғылар идәчәгеңез (قایغولر ایده چككز) хыйалымда йук иде [Фәхретдин, 1899, б. 23]; Шәриғәт вә ғакыл хилафында бер шәй тәклиф итмәйәчәгеңез (تكلیف ایتمیه چككز) мәғлүм улдығы ичүн, һәр әмереңез башым өстендәдер [Фәхретдин, 1899, б. 77]; ...нә кәдәр идеге ачык мәғлүм улмаз исә дә бер бең рубләдән аз улмайачағы (آز اولمیه جغی) тәхмин иделенер [Фәхретдин, 1903, б. 33]; Затән ихлас илә укымыш улса да, тырышып укымыш башка

балаларың һичбер шәй белмәдекләре кеби буның һәм һичнәрсә белмәйәчәге (بيلميه جكى) әшкарә иде [Фәхретдин, 1903, б. 47] һ.б.;

2) төшем килешендә: ...тиз көндән бу рәхәт урынларны күрәчәгемне (كوره چكمنى) өмид идеп күңелеме йуата идем [Фәхретдин, 1899, б. 8]; Бу кеби хөрмәтле дустлардан айырылып кидәчәгемне (كيده چكمنى) вә бундан соң нә кеби урынлара варып кемләр илә мәҗлестәш улачагымны (اولاچغمنى) фикерләп әсәрләнмәкдә идем [Фәхретдин, 1899, б. 9]; Бунлар Әсманың киләчәк көнләрене берәм-берәм дийәрлек тәфәккер қылырлар, хәтта ки нә кеби зата тапшырачақларыны (تابشره چقلرنى) да дөшенерләр иде [Фәхретдин, 1903, б. 15]; Һәм дә эшне белешдегене, әгәр дә хатны Ғаббас мелла йаздығы дәлил илә исбат иделсә, Ғаббас мелла һәм Муса йанына кидәчәгене (كيده چكنى) сөйләде [Фәхретдин, 1903, б. 35] һ.б.;

3) чыгыш килешендә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен күрсәткәндә: Мәзкүр китаб тәхлил иделенүб дә йалан, ифтира, ғайбәт, бохтанлары вә мақсуда мөнәсәбәте улмағанлары чықарылса иде, саф ақ кәғәз улып қалачағындан (قاله چغندن), ... бу китаб Хикмәт бай ичүн файда вирәчәк дәгел иде [Фәхретдин, 1903, б. 31]; ...ғөмер барынча йитәрлек улан байлықдан мәхрүм улачағындан (محروم اوله چغندن) қурқып, дилене тыйып асрамақда иде [Фәхретдин, 1903, б. 101].

*-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыльләре Ф. Кәрими сәяхәтнамәләрендә дә еш очрый. Автор аларны атрибутив позициядә, исем фигыль буларак һәм *-ырға* инфинитив формасы урынында куллана. Атрибутив позициядә килгән *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләргә Язучы түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә:

1) предмет яисә затның киләчәктә башкарылачак эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен күрсәткәндә: Бинаи ғаләйһи без дәхи кидәҗәгемез (كيده جكمز) мәмләкәтләрең бақып дәрәҗәи мәғмурийәтләрене нәзар иғтибара алдық [Кәрими, 1902, б. 3]; Ләкин «Рәһнамә» илә харита һәрwақыт әлдә булынмалы вә һәр көн ақшам йарын киделәҗәк (كيديله جك) йирләр тәғаен иделмәледер [Кәрими, 1902, б. 83]; Мосахәбәт итдек, ыпересе көн 4 нҗе майда кәнде ханәсендә wақыйғ улаҗақ (واقع اوله جق) доға мәҗлесенең сабах ундан итибарән башлайаҗағыны бәйан итде [Кәрими, 1908, б. 62] һ.б.;

2) предмет яисә затка гомумән хас булган процессуаль билгене тасвирлаганда *-а торған* кушымчалы сыйфат фигыльләр урынында: Һәрбер классында әшйа қуймақ ичүн пәк гәниш йирләре, абдәстханәләре, йықанаҗақ (ييقانه جق) йирләре, вә йатақлы вагонларда һәр кеше

ичүн истәдеге кеби узанып йатаҗак (ياته جق) урынлары, хақыйқатә, пәк мөкәммәлдер [Кәрими, 1902, б. 6]; Нәзар ғибрәт илә моталәға улындықда, циркларда дәхи ғибрәт алынаҗақ (عبرت آلنه جق) пәк чуқ шәйләр вардыр [Кәрими, 1902, б. 19]; ...мәктәбең бақаҗақ (باقه جق) вә төзәдәҗәк (توزه ده جك) йирләре улдықда, безә сөйлә [Кәрими, 1908, б. 36]; Төрекләр, ғарәбләр вә Қырым илә Кавказ халқларында вә хәтта қырғызларда билә һәр wақытда мәҗлесе хуш кичерәҗәк (كچره جك) нәшәле сүзләр булыныйур вә хуш сөхбәтләр иделийур [Кәрими, 1908, б. 63] һ.б.

Сәяхәтнамәләр өчен *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең *дәрәҗәдә* (درجه ده) сүзе белән бергә башка эш-хәрәкәтнең, яисә персонажга, объектка хас булган сыйфат-билгеләрнең дәрәҗәсен күрсәтү өчен кулланылулары да хас: Китабларының әксәрәте нәзар диққате җәлеб идәҗәк дәрәҗәдә (جلب ايده جك درجه ده) иде [Кәрими, 1902, б. 28]; Бульварларың ике тарафындағы бүйүк биналар вә магазалар ғақыллара хәйрат вирәҗәк дәрәҗәдә (حيرت ويره جك درجه ده) бүйүк вә монтазамдыр [Кәрими, 1902, б. 107]. ... анларың даимән суланып тәмиз тотылмасы шашылаҗақ дәрәҗәдәдер (شاشيله جق درجه ده در) [Кәрими, 1902, б. 125]; Аурупа әһалисенең ... тәрәққыяте безем хыйалымыза билә кермәйәҗәк дәрәҗәдә (كيرميه جك درجه ده) ғалидер [Кәрими, 1902, б. 161] һ.б.

Исем фигыль урынында *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләр киләчәктә башкарылачак эш-хәрәкәтне атап киләләр. Автор аларны түбәндәге рәвештә файдалана:

1) баш килештә: Бүйүк шәһәрләрдәге моғтәбәр тиатроларда ханги көн насыл уйын күстәреләҗәге (كوستريله جكى) беркач көн әүwәл иғлан улыныып билетлары дәхи сатылмаға башлыйур [Кәрими, 1902, б. 37]; Гәрчә нимсәҗә лисан белмәдегемез җәһәтлә бундан истифадә иделмәйәҗәге (استفاده ايدلميه جكى) мәғлүм иде исә дә,... [Кәрими, 1902, б. 75]; ...дамарларында туңмыш улан қаны мәдәнийәте җәдидәнең зыйа вә харәрәте илә йаңардылып хәрәкәтә китерелмәйәҗәк улырса, бичара милләтең зәвал вә инқыйраза мәхкүм улаҗағы (محكوم اوله جغى) аңлашылмақда иде [Кәрими, 1902, б. 134] һ.б.;

2) юнәлеш килешендә: «Халик ләкем ма фил әрз җәмиға» серенә мозһир улаҗақларына (مظهر اوله جقلرينه) шөбһә йуқдыр [Кәрими, 1908, б. 29];

3) төшем килешендә: ...музәйә нәрәдән кереләҗәгене (كيريله جكنى) бәлзарур бу ханымдан сурдық [Кәрими, 1902, б. 44]; Бурада поездың пәк аз тораҗағыны (طوره جغنى) әүwәлдән хәбәр алмыш идек [Кәрими,

1902, б. 61]; ...Оренбургдан нә wақыт чығаҗағымызы (چيقه جغمزى) бер ачық хат илә әүwәлдән хәбәр виреп қуймыш идем [Кәрими, 1908, б. 8]; Барышня безем кем улып нәрәйә китдегемезе вә без аның нәрәле улдығыны вә безем илә бәрабәр чуқ мөддәтме вараҗағыны (واره جغنى) сурдық, таныштық, сүз ачылды [Кәрими, 1908, б. 16] һ.б.;

4) чыгыш килешендә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен күрсәткәндә: Сәғәт йидедә Сызрана киләрәк, бурада поезд йарым сәғәт қәдәр тәүкыйф идәҗәгендән (توقف ايده جكندن) вокзала чықып тәғам йидек [Кәрими, 1902, б. 7-8]; Әгәр йалғыз фиһрәстдә мөндәриҗ уланларының һәпсене йазаҗақ улсам, дәхи пәк узун кидәҗәгендән (كيده جكندن), бу қәдәр илә иқтифа идийурум [Кәрими, 1902, б. 50]; ...бунларың ән бүйүк вә мөһимләрене Берлинда күрдегемез вә йақында Париж илә Венада дәхи күрәҗәгемездән (كوره جكمزدن) у қәдәр әһәмийәт вирмәдек [Кәрими, 1902, б. 98] һ.б.;

5) урын-вакыт килешендә: Аның илә берлекдә йәни хөқаманың дәхи мәсләкләрендән вә фикерләрендән хәбәрдар улсалар иде, чуқ файдасы улаҗағында (اوله جغنده) асла шөбһә йуқдыр [Кәрими, 1902, б. 10].

Сәяхәтнамәләрдә *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең қәдәр (قدر) бәйлеге белән бергә кулланылу очраклары да теркәлде. Әлеге конструкция автор тарафыннан билгеле бер предметка яисә күренешкә хас булган сыйфатның дәрәҗәсен күрсәткәндә файдаланыла: Бу фикерә хезмәт идәнләрең мақсады: қадынлары әркәкләрең наил улдықлары хоқуқ кяффәсенә наил идеп, мөтәсәви әл хоқуқ итмәк вә қадынларың әленә кәнде мәғыйшәтләрене кәнделәре тәэмин идәҗәк қәдәр (تأمين ايده جك قدر) иқтидар виреп, әркәкләрең әсире хөкемендә улып тормақдан тәхлис итмәкдер [Кәрими, 1902, б. 145]; Бу кеби бичараларың әксәресе кәнде кәндене гиздерәҗәк қәдәр (كزديره جك قدر) қуәтә малик улмадығындан вә хальбуки бунларың адәми хәйәте ичүн саф һаwа тәнәффес итмәк ән беренҗе шарт улдығындан, Миранда дүрт тәгәрлекле кечек-кечек арабалар япмышлар [Кәрими, 1902, б. 150] һ.б.

*-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең барысы өчен дә хас. Шул ук вакытта аерым авторларда аларның кулланылышында кайбер үзенчәлекләр дә күзәтелә. Мәсәлән, З. Бигиев, Р. Фәхретдин әсәрләрендә һәм Ф. Кәрими сәяхәтнамәләрендә бу сыйфат фигыльләр атрибутив позициядә һәм исем фигыль буларак кулланылсалар, М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында алар бары тик исем фигыль функциясендә генә теркәлделәр. Моннан тыш,

аерым очракларда *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләрне мәгърифәтче язучылар *-а торған* кушымчалы сыйфат фигыльләр һәм *-ырға* инфинитив формасы урынында да файдаланалар.

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-ачақ (-аҗақ)* кушымчалы сыйфат фигыльләр ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда, шигъри әсәрләрдә, газета текстларында һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә кулланылалар [Шамарова, 1990, с. 78; Юсупов, 2006, с. 114–115; Миннуллин, 2012, с. 198; Абдулхаков, 2007, с. 21]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норманың бер күрсәткече булып торалар.

*-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләр. Хәзерге татар әдәби телендә *-ган* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләр атрибутив позициядә төрле мәгънәдәге (субъект, объект, урын, вакыт) сүзләр белән кулланылалар һәм аларны, нигездә, үткәндә башкарылган эш-хәрәкәт буенча ачыклап киләләр, ләкин бу сыйфат фигыльләрнең заман мәгънәсе җөмләдәге төп эш-хәрәкәтнең заманы белән билгеләнә. Билгеле бер контекстта *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләр сыйфатланмышларыннан башка, ягъни исемләшкән хәлдә һәм исем фигыль буларак та кулланыла алалар [Татарская грамматика, 1997, с. 201–211; Тумашева, 1978, б. 140–144; Хисамова, 2006, б. 230–239].

Әлеге сыйфат фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы иске татар язма чыганакларыннан, нигездә, әдәби әсәрләрдә еш очрый. Сәяхәтнамәләр өчен аларның кулланылуы хас түгел. Мәгърифәтче Язучылар *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләрне, автор сөйләмендә куллану белән бергә, персонажлар сөйләменә дә кертеп җибәрәләр. Мәсәлән:

Урамның бер читендә бишмәтләренә йабынып ике қадын сүзләшийурлар:

– Сән қайда болай бик иртә барасың тутай? – сурды йәшрәк қадын.

Икмәкләремне пичкә қуйғанда (قويغانده) көрәгем йарылды, көрәк сорарға барамын балақай! – җаwабланды қарт қадын [Акъегет, 1886, б. 51];

...

«Унике сәғәтдә кидүене йақыйнан нәдән белдең?» – дийү сөаль қылдықда, хадим-швейцар бу тариқа җаwаб вирде: «Чөнки мәрхүмә

илә бәрабәр килгән (كلكان) адәм номерәләрдән кидәркән: «Қач сәғәт?» – дийү бәндән сөаль қылды... [Бигиев, 1887, б. 6];

...

– Қайда кәтде?.. Киткән (كتكان) wақытда әйткәндер, фәлән йиргә барамын, дип?

– Киткән (كتكان) wақытда әйтде, аwылға қунақ булып барамын дип. Ләкин аwылға бардымы-йуқмы – аны белмимен [Бигиев, 1890, б. 39].

Язма чыганакларда әлеге сыйфат фигыльләр *-ған/-гән/-қан/-кән* (-غان/-قان/-كان/-كان) кушымчасы ярдәмендә ясалалар: йәрләшдергән (يرلشدركان) заманда [Акъегет, 1886, б. 9], раст килгән (راست كلكان) wақытда [Акъегет, 1886, б. 20], ишеделмәгән күрелмәгән (ايشدولمكان كورولمكان) бер сурәтдә [Акъегет, 1886, б. 53], килгән (كلكان) адәм [Бигиев, 1887, б. 6], табылған (طابلغان) сул қул пирчәткәсе [Бигиев, 1887, б. 7], мәқтүл булған (مقتول بولغان) көнендә [Бигиев, 1887, б. 8], җәмәғәт ултырышқан (اولتروشقان) бүйүк бүлмәйә [Бигиев, 1887, б. 38], кәткән (كتكان) wақытда [Бигиев, 1890, б. 18], сөйләгән (سويله كان) сүзләр [Бигиев, 1890, б. 18], мән әйткән (ايتقان) эш [Бигиев, 1890, б. 62], хан мәсҗеде дия мәшхүр улған (مشهور اولغان) бүйүк манара [Фәхретдин, 1899, б. 3], әйткән (آيتكان) нәсихәте [Фәхретдин, 1899, б. 4], ислам мәдрәсәләрендә тәхсил иткән (تحصيل ايتكان) ғоләмә [Фәхретдин, 1899, б. 10], йөзләренә салған (سالغان) челтәр пәрдәләре [Фәхретдин, 1899, б. 15], буйға йиткән (بويغه يتكان) ике уғлы [Фәхретдин, 1903, б. 48], виргән (ويركان) садақаларымызы [Фәхретдин, 1903, б. 68], бунда җыелған (جيولغان) кешеләр [Фәхретдин, 1903, б. 80], уйқуларындан иртә уйғатқан (اويغاتقان) вә мәктәбә йөгерткән (يوكرتكان) нәрсә [Фәхретдин, 1903, б. 83], һич өмид иделмәгән (اميد ايدلمكان) лотыфлара [Фәхретдин, 1903, б. 116] һ.б.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләр атрибутив позициядә, нигездә, *заман* (زمان) һәм *wақыт* (وقت) сүзләре белән кулланылалар. Бу очракта алар җөмләдәге төп эш-хәрәкәт белән бер вакыт яссылыгында башкарылган процессны бедереп киләләр. Әсәрдә *-ған заман/wақыт* конструкциясе төп эш-хәрәкәтнең үтәлеш вакытын күрсәткәндә файдаланыла: Атны сарай астында йирләшдергән заманда (يرلشدركان زمانده) менланың күзенә гүзәл бер күренеш раст килде [Акъегет, 1886, б. 9]; Ахыр Хәнифә туташа да менла илә уғрашмақ дәхи хуш иде, чүнкә раст килгән wақытда (راست كلكان وقتده) қыз вә җегет бер беренә бақышмаға башладылар [Акъегет, 1886, б. 20] һ.б.

Әсәрдә *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең исем фигыльләр урынында кулланылу очраклары да теркәлде. Әлеге позициядә алар урын-вакыт килеше кушымчаларын алалар һәм төп эш-хәрәкәт белән бер вакыт яссылыгында башкарылган процессны белдерәләр, ягъни *-ған заман/wақыт* конструкциясен алыштырып киләләр: Хәтта ки мөдәррис хәзрәтләре йортқа гәзмәгә чыкқанда (چققانده) майлы ашларның қухусы вә исе ашханәдән борынына йетешүб ... деле дәрйасындан төкерек чыкды [Акъегет, 1886, б. 35]; Иғанә ақча сурғанда (صورغانده) ничүн бәгзе исламлары хурладың? [Акъегет, 1886, б. 62] һ.б.

З. Бигиевнең романнарында *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләр күбрәк атрибутив позициядә кулланыла. Аерым очракларда исем фигыльләрне алыштырып киләләр. «Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» сәяхәтнамәсендә бу сыйфат фигыльләрнең сыйфатланмышыннан башка, ягъни исемләшкән хәлдә кулланылу очраклары да теркәлде: Ашлары ит, май улып, эчкәнләре (ایچدکلری) хайwан сөтедер [Бигиев, 1908, б. 22].

Атрибутив позициядә автор *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләрне предмет яисә затның үткәндә башкарылган эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен тасвирлаганда файдалана: Тәфтишчеләр мәктүлә илә бәрабәр килгән (كلكان) адәмнең исеме Муса улдығыны да мәктүбдән белделәр [Бигиев, 1887, б. 8]; Господин Шубин йанындағы өстәлдә сағ қулдан бер danә ир пирчәткәсе күреп, мәктүлә Зөләйханың номерендән тәфтиш wақытында табылған (طابلغان) пирчәткәнең ибдәше идегене аңлыйдыр [Бигиев, 1887, б. 12]; Әхмәди бай да ивенә қайтып барғач, хатынына господин Андреевның қылған (قلغان) мәслихәтене гүзәл идеп сөйләде [Бигиев, 1887, б. 29] һ.б.

Әсәрләрдә *-ған* кушымчалы фигыльләр атрибутив позициядә, еш кына, *wақыт* (وقت) сүзе белән кулланылалар. Бу очракта алар җөмләдәге төп эш-хәрәкәт белән бер вакыт яссылыгында башқарылган процессны белдереп киләләр. *-ған wақыт* конструкциясе автор тарафыннан төп эш-хәрәкәтнең үтәлеш вакытын күрсәткәндә файдаланыла: Шимди исә, ахунд хәзрәтләренә тәғзимән утырышқан кешеләр торып утырған wақытда (اولترغان وقتده), урынсызлар да тығызланыпнидеп, җәмәғәт арасына утырышдылар [Бигиев, 1887, б. 38]; Сез бәне ашадып-эчереп тотарсыз, үзеңез қайтқан wақытда (قايتقان وقتده) мәне дә Қазанға алып қайтырсыз [Бигиев, 1887, б. 55]; Ул буйақчыларны мән иртә килгән wақытларында (كلكان وقتلرنده) күргән идем [Бигиев, 1890, б. 71] һ.б.

Исем фигыль урынында *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләр үткән заманда башкарылган һәм хәзерге заманга караган эш-хәрәкәтләрне атап киләләр. Автор аларны түбәндәге рәвештә файдалана:

а) баш килештә: Кәсеб ..., хайр кәсеб қылғаны (كسب قلغانى) бер дә беленми... [Бигиев, 1890, б. 43];

ә) юнәлеш килешендә: Хатыным үлгәнгә (اولكانكا) ... ике йыл булды [Бигиев, 1890, б. 43];

б) төшем килешендә: Қартчығның мәслихәт вә тәғлим қылғанына (تعليم قيلغاننى) Маһруйның следовательгә сөйләгән сүзләрене ... Ибраһим нәқыл қылғач, қартчығымызның күзләре чашқалар қәдәр улып дүрт улды [Бигиев, 1890, б. 29-30]; Менә следователь хозурына барғач сөйләшеп қарармыз, нә белгәнемне (بلكانمنى) белерсең... [Бигиев, 1890, б. 46];

в) урын-вакыт килешендә башка эш-хәрәкәтнең үтәлеш вакытын күрсәткәндә: Мән өйдән кәткәндә (كتكانده) дә эчәргә китеп қалды [Бигиев, 1890, б. 47]. Сезне хәбесханәйә кергәндә (كركانده) вә чықғанда (چيقغانده) қарамыйлар... [Бигиев, 1890, б. 66].

Әсәрләрдә *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең *кеби* (كبى), *қәдәр* (قدر), *бирү* (بيرو) бәйлекләре белән бергә кулланылыш очраклары да теркәлде.

*-ған кеби* конструкциясенә автор башка эш-хәрәкәтнең башкарылу рәвешен тасвирлаганда мөрәҗәгать итә: Муса әфәндейе мәхкәмәдән үле кешейе чықарған кеби (چقارغان كبى) күтәреп чықардылар [Бигиев, 1887, б. 47]; Алла сақласын, утдан вә хатындан қурықған кеби (قورقغان كبى), шу мөскиратдан сақланыңыз вә қурқыңыз! [Бигиев, 1890, б. 28]; Үз баламны тәрбийә қылған кеби (تربيه قيلغان كبى) тәрбийә қылырмын [Бигиев, 1890, б. 28] һ.б.

*-ған қәдәр* конструкциясе: Ғабденнасыр әфәнде илә Ғабдуллин чәйханәдән чығып киткәч, дүрт-биш дакикадан соңра зи зәкәвәт улан господин Шубин да ғарақы үчүн охшаған қәдәр (اوخشاغان قدر) ақча вирүб, чәйханәдән чығып китде [Бигиев, 1887, б. 49]; Господин Шубин Ғабденнасыр әфәндедән алған әшйалар үчүн Ғабденнасыр әфәндейә охшаған қәдәр (اوخشاغان قدر) ақча виреп, номердән чығып китде [Бигиев, 1887, б. 58].

*Бирү* (بيرو) бәйлеге белән *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләр чыгыш килешендә кулланылалар һәм әлеге конструкция башка эш-хәрәкәтнең вакыт ягыннан башлангыч ноктасын белдерә. Ләкин язма чыганакларда *-ған бирү* конструкциясенең бары тик бер генә

кулланылыш очрагы теркәлде: Күбдән, бай (хуҗа) бу йортны алғандан бирү (آلغاندن بيرو) бу йортда торамын... [Бигиев, 1890, б. 43].

Күп кенә очракларда автор *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләрне *бар* (بار) һәм *йуқ* (يوق) хәбәрлек сүзләре белән бергә файдалана. Әлеге конструкцияләр, нигездә, персонажлар сөйләмендә очрый. Автор аларны үткәндә башкарылган яисә башкарылмаган нинди булса вакыйга турында хәбәр иткәндә файдалана: Үземез хәбәр иткәнемез йуқ (خبر ايتكانمز يوق), белми торғандыр [Бигиев, 1887, б. 16]; Бәли, башқа номерләрдә торырға да күп туғры килгәне бар (طوغرى كلكانى بار)... [Бигиев, 1887, б. 28]; Баланың әткәсене, бер-ике ай миқдар улды, күргәнем дә йуқ (كوركانم ده يوق), ақча вирерме икән?! [Бигиев, 1890, б. 21]; Менә, менә, мәнем сүзләрем-мәслихәтем тәмам булғаны йуқ (تمام بولغانى يوق) [Бигиев, 1890, б. 32] һ.б.

Р. Фәхретдиннең әсәрләрендә *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләр, нигездә, атрибутив һәм субстантив позицияләрдә кулланылалар. Шул уқ вакытта аларның исем фигыль мәгънәсендә кулланылышы да теркәлде. Атрибутив позициядә килгән *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләргә автор түбәндәге максатларда мөрәҗәгать итә:

а) предмет яисә затның үткәндә башкарылган эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен күрсәткәндә: Әйткән (آيتكان) нәсихәте күңелемнең эчендәдер [Фәхретдин, 1899, б. 4]; Қазанда улған мәдрәсәдә ун сәнә ғөмер уздырып, уқыған (اوقوغان) дәресләрем күб, белгән (بيلگان) нәрсәләрем чиксез, күтәргән (كوترگان) китабларым хисабсыз иде [Фәхретдин, 1899, б. 6]; Һәр йирдә очраған (اوچراغان) балалар сәлам виреп әдәб илә үтүб кидәләр [Фәхретдин, 1903, б. 82]; Дәрестә ишеткән (ايشتكان) файдалы нәрсәләреме сөйләргә көчем йитмәз [Фәхретдин, 1903, б. 84] һ.б.;

ә) предмет яисә затка гомумән хас булган билгене тасвирлаганда: Холқы гүзәл улмаған (گوزل اولمغان) кешене адәмләр сәүмәзләр [Фәхретдин, 1899, б. 5]; Бу шәһәрнең биналары, урамлары, мәсҗетләренең күккә чыкған (چقغان) манаралары, җөмләсе мәхәббәтле күрелмәкдә иде [Фәхретдин, 1899, б. 8]; Ойалмаған (اويالمغان) кемсәнә дөнйада нә эстәсә, шуны қылыр... [Фәхретдин, 1899, б. 44]; Хатынлар ислам милләтендә беренче дәрәҗәдә хөрмәтле, иғтибар иделгән (اعتبار ايدلگان) затлардыр [Фәхретдин, 1899, б. 68]; Исерткеч эчмәк дәгел, исерткеч эчкән (ايچكان) кемсә илә хәтта мәҗлесдәш улмаз иде [Фәхретдин, 1903, б. 23] һ.б.

*-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләрне язучы әсәрләрендә сыйфатланмышларыннан башка да файдалана. Бу очракта алар үзләренә

исем сүз төркеменә хас грамматик категорияләрнең күрсәткечләрен алалар. Әсәрләрдә теркәлгән исемләшкән *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләр эш-хәрәкәтнең башкаручысын атап киләләр һәм түбәндәге рәвештә кулланылалар:

а) баш килештә: Ғорбәтдә улғанлар (غربتده اولغانلر) аз хезмәтне дә күб вә олуғ хисаб идәрләр [Фәхретдин, 1899, б. 33]; ...йәш ғөмердә тырышқанлар (ترشقانلر) қартлықда рәхәт күрерләр [Фәхретдин, 1899, б. 34]; Ғәрләнгән (عارلنگان) илә ойалған (اويالغان) ғыйлемсез қалыр [Фәхретдин, 1899, б. 58]. Бурычны яшергән (ياشرگان) бөлгән, чирне яшергән (ياشرگان) үлгән [Фәхретдин, 1899, б. 62] һ.б.;

ә) юнәлеш килешендә: Бу мәктәпләрдә исә йәшлегендә мәктәб күрмәгәнләргә (كورمگانلر گا) файда улсын ичүн дин вә холық туғрысында дәресләр вирелер [Фәхретдин, 1899, б. 70]; Очраған wақытда йырақдан торып сәлам вирмәгәнләрә (سلام ويرمكانلره) йәки хөрмәт күстәрмәкдә қосурлық идәнләрә (قصورلق ايدنلره) бер wақытыны туры китереп җәзасыны вирер иде [Фәхретдин, 1903, б. 15];

б) төшем килешендә: Аллаға шөкер, ничә еллар Қазан шәһәрендә олуғ бер мәдрәсәдә тәхсил идеп, бер қызның сүзләгәнләрене (سوزلگانلرنى) аңлар, йәки аңлаған кемсәнә мисалында дыңлар қәдәр Камаләт кәсеб итмеш имешем! [Фәхретдин, 1899, б. 50–51]; Анлар һәм үз күргән (كوركان), үз белгәнләрене (بيلكانلرنى) сөйләделәр [Фәхретдин, 1903, б. 85] һ.б.

Исем фигыльләр урынында килгән *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләр үткәндә башкарылган эш-хәрәкәтне атап киләләр. Язучы аларны түбәндәге рәвештә файдалана:

1) төшем килешендә: Үлгәнемне (اولگانمنى) ишетсәң, доға қылырсың [Фәхретдин, 1899, б. 5]; Беренең қайчан башланғаныны (باشلانغاننى) белүче қартларымыз бар, әмма беренең башланғаныны (باشلانغاننى) һич белмәйләр [Фәхретдин, 1903, б. 81]; Балаларының намаз уқып йөргәнене (يوركاننى) күргән соң, ата вә аналары һәм уқырға ғәдәтләнгәнләр [Фәхретдин, 1903, б. 82].

2) урын-вакыт килешендә:

а) башка эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын күрсәткәндә: Пароход хезмәтчеләренең ашығып нәрсә ташулары, йағмур күрелгәндә (كورلگانده) ашлық уручыларның йөгерә-йөгерә көлтә җыймақларыны искә төшерә иде [Фәхретдин, 1899, б. 14]; Безнең Қазан байларының хатынлары, ирләре үлгәндә (اولگانده) үкерүб-үкерүб йығлаб, иртәге көнендә көлә-көлә йәш кийәүгә кидәләр иде... [Фәхретдин, 1899, б. 34];

Бәлки килгәндә сез һәм мәзкүр аwылы үтүб килгәнсездер [Фәхретдин, 1903, б. 81];

ә) башка эш-хәрәкәтнең башкарылу шарты турында сөйләгәндә: Русча йахшы белмәгәндә (بيلمكانده) бунларны мәйданға қуймақ мөмкин дәгел идеге шөбһәсездер [Фәхретдин, 1899, б. 19]; Тырышып тәрбийә вирелгәндә (تربيه ويرلكانده), барысы улмазса да, күбесе ирешәдер [Фәхретдин, 1903, б. 111].

Бик сирәк очракларда язучы исем фигыль урынында килгән *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләрне башка килешләрдә дә куллана:

б) баш килештә: Сәғәтләр илә сүзләшүб сохбәт идеп утырмақда исәм дә, заман үткәне (اوتكانى) беленмәйдер иде [Фәхретдин, 1899, б. 71];

ә) юнәлеш килешендә: Иртә барсақ, сабақны йахшырақ уқырға була, йахшы уқығанға (اوقوغانغه) рәхмәт була [Фәхретдин, 1903, б. 83];

б) чыгыш килешендә: Ошбу хикмәткә бинаән қазанлыларның сәүдә ғәмәлләрене тиҗарәт китабларындан һәм дә ошбу сәнәдә йазылғанындан (يازلغانندن) қарармыз [Фәхретдин, 1899, б. 59–60].

Р. Фәхретдин әсәрләрендә *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең қәдәр (قدر), ичүн (ايچون), соң (سوڭ) бәйлекләре белән бергә кулланылу очраклары да теркәлде.

*-ған қәдәр* конструкциясенә автор башка эш-хәрәкәтнең вакыт ягыннан үтәлеш чиген күрсәткәндә мөрәҗәгать итә: Һәр нә қәдәр қамил сәламәт дәгел исәм дә, сәне мәктәпкә йибәргәнгә қәдәр (يبلرگانگه قدر) дийә, Аллаһы Тәғаләдән ғөмеремә форсат сорамыш идем [Фәхретдин, 1899, б. 5]; Бала wақытында ишеткән сүзне күп кешегә сақалы ағарғанға қәдәр (آغارغانغه قدر) ташларға муафыйқ улмайдыр [Фәхретдин, 1899, б. 69]; Әмма Хикмәт хаҗи Ғаббас мелланы Муса йанына йибәргәнгә қәдәр (يباركانكه قدر) сығи идәчәк улдығындан... [Фәхретдин, 1903, б. 36].

*-ған ичүн* конструкциясе башка эш-хәрәкәтнең үтәлү сәбәбен белдерә. Ләкин аның бары тик бер генә кулланылыш очрагы теркәлде: Шәкердләргә мөнасиб кийемләремне кийүб йөргәнем ичүн (يورگانم ايچون) бәғзе бер мөселманлар сәлам виреп әшналық идәләр вә Бәғзеләре мәхкәмә рәисе қәдәр хәлемне тәфтиш қылалар иде [Фәхретдин, 1899, б. 23].

*-ған соң* конструкциясе башка эш-хәрәкәтне үтәлү вакыты ягыннан ачыклап килә: Пароходға кергән соң (كرگان سوڭ) урын тапмай мөшкеллек чикдекләре, қапитанға хәлләрене аңладырлық дел белмәдекләрендән улмышдыр [Фәхретдин, 1899, б. 33]; Әмма Зәйнәб бу

шәһәргә килгәнемез соңында (کلگانمز سوڭنده) яңа тәртиб (йиңел уқымақ) илә уқыды [Фәхретдин, 1899, б. 41]; ...бөтен җәмәғәтне қан ағлатқан соңында (قان آعلاتقان صوكنده) бер ай тормай, уғлы җен кебек сәламәт қайтып килде [Фәхретдин, 1903, б. 81]. Бу аwыла ошбу қыш чана йулы дөшкән соң (دوشكان صوك) бардым [Фәхретдин, 1903, б. 82].

*-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең барысында да кулланылалар. Чыганакларда алар сыйфат фигыльләр өчен хас барлык позицияләрдә дә теркәлделәр.

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-ған* кушымчалы сыйфат фигыльләр ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда, шигъри әсәрләрдә һәм газета текстларында кулланылалар [Шамарова, 1990, с. 78, Юсупов, 2006, с. 109–110, Миннуллин, 2012, с. 194–195]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар, дини-фәлсәфи хезмәтләрдән кала, бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норма, норма вариантлылыгының бер күрсәткече булып торалар.

*-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләр. *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләр госманлы төрек теле үзенчәлеге санала. Алар зат яисә предметны үткән һәм хәзерге заманга караган эш-хәрәкәт буенча ачыклап киләләр. Моннан тыш, сөйләм барышында сыйфатланмышының билгеле бер заманга карамаган процессуаль билгесен дә белдерергә мөмкиннәр [Кононов 1956, с. 252, 471]. Әлеге сыйфат фигыльләр хәзерге татар әдәби телендәге *-ган* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләренең грамматик синонимнары булып торалар.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы иске татар язма чыганакларында *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең, нигездә, атрибутив позициядә һәм исемләшкән хәлдә кулланылуы күзәтелә. Исем фигыль мәгънәсендә алар сирәк очрый. Әлеге сыйфат фигыльләрнең, сыйфатланмышлары урынында алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең субъекты, объекты, башкарылу урыны һәм вакыты мәгънәсендәге сүзләр килә. Алар фигыль нигезенә *-ан/-ән* (ان-/ن ه-/ن-) кушымчасы ялганып ясала: хезмәт сәвән (سون) адәм [Акъегет, 1886, б. 2], үлем түшәгендә йатан (يتان) кеше [Акъегет, 1886, б. 5], раст килән (راست كلن) кийем [Акъегет, 1886, б. 56], йанан (يانان) фәнәрләр [Акъегет, 1886, б. 56–57], әтрафда булынан (بولنان) аwыллар [Акъегет, 1886, б. 63], күрергә эстәйән (استيان) адәм [Бигиев, 1887, б. 10],

Ғабдуллин күстәрән (كوسترن) кәғәз [Бигиев, 1887, б. 48], дәләләт қылан (دلالت قيلان) шәй [Бигиев, 1887, б. 51], қәтелдә мәғйүб улан (معيوب اولان) кеше [Бигиев, 1887, б. 67], тиҗарәт вә хезмәт идән (تجارة و حذمت ايدن) кемсә [Бигиев, 1890, б. 4], Ғабделхақ утыран уқый-ан (اوتره ن اوقويان) мәдрәсә [Бигиев, 1890, б. 11], Маһруйны килтерән (كلترن) солдат [Бигиев, 1890, б. 26], қәтел идән (قتل ايدن) хатын [Бигиев, 1890, б. 37], мөскират улан (مسكراة اولان) шәйләре [Бигиев, 1890, б. 48], хасыйл улан (حاصل اولان) ашлық [Бигиев, 1908, б. 15], мөхәлләфәт идән (مخالفت ايدن) йәзидләр [Бигиев, 1908, б. 20], йәрдәм итмәгә қасд идән (قصد ايدن) татар [Бигиев, 1908, б. 22], Йаурупа фабриқалары ғаҗиз улан (عاجز اولان) эшләре [Бигиев, 1908, б. 45], Мерв ханлығы тәхетендә җөлүс идән (جلوس ايدن) зат [Бигиев, 1908, б. 55], озатмаға килән (كلن) адәмләрең [Кәрими, 1902, б. 5], вокзаллара күндәрелән (كوندريلان) бу арабалар [Кәрими, 1902, б. 11], дөрле дилләр белән (بيلن) адәмләр [Кәрими, 1902, б. 13], тиҗарәт идән (تجارت ايدن) мөселман [Кәрими, 1902, б. 23], ғарәбҗә үгрәнмәк ичүн чалышан (چاليشان) адәмләр [Кәрими, 1908, б. 19], Қара диңгезә бақан (باقان) бийек дағларың [Кәрими, 1908, б. 32], Ләһстан үзәренә һөҗүм идән (هجوم ايدن) Қырым ғаскәренең [Кәрими, 1908, б. 45], дөнйайы нурландыран (نورلندران) гүнәшең зыясы... [Кәрими, 1908, б. 46], тәхсил идән (تحصيل ايدن) хамиятле гәнҗләремез [Кәрими, 1908, б. 84], хезмәт вә ғайрәт күстәрән (خدمت و غيرت كوسترن) ғаскәрләрең [Кәрими, 1908, б. 93], беренче дәрәҗәдә лйазем улан (لازم اولان) шәйдер [Фәхретдин, 1903, б. 6], wафат идән (وفات ايدن) мәшһүр бер философ [Фәхретдин, 1903, б. 6], ғыйлем мәртәбәсене вә адәм мәртәбәсене белән (بيلن) адәм [Фәхретдин, 1903, б. 14], гүзәл шиғерләре сөйләйән (سويليين) Закирең [Фәхретдин, 1903, б. 21], аның сарыф идән (صرف ايدن) ақчасыны [Фәхретдин, 1903, б. 35] һ.б.

М. Акьегетнең «Хисаметдин менла» романында *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләр, нигездә, автор сөйләмендә, пейзаж тасвирламаларында кулланыла. Шуның белән бергә автор аларны персонажлар сөйләменә дә кертеп җибәрә. Мәсәлән:

– Бәлки туғры, әмма хәбес иделмәсенә сез сәбәбҗе улдығыныза без һич инанмыйуруз.

– Әлбәттә, менла Хисаметдин хәбес итдермәз, чүнкә ул ислам сәвән (سون) адәмдер; йәтим саилләрен нәфәқатләрене кәсмәк исә наданлықдан килер вә кяфер эшедер, – бәйан әйләде Бикбулат менла вә шәкердләренә күз йомды [Акъегет, 1886, б. 15–16].

Атрибутив позициядә килгән *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләргә автор түбәндәге максатларда мөрәҗәгать итә:

а) предмет яисә затның үткәндә башкарылган эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен күрсәткәндә: Һәр нә қәдәр Хисаметдин менла бөйлә шәкердән илә сүзләшмәк эстәмәде исә дә, ләкин кяфер эше дәнилән (دينلان) сүзләренә чыдамайып, бөйлә җаwаб вирде... [Акъегет, 1886, б. 16]; Хәнифә туташ эленә раст килән (راست كلن) кийемене кийеп тирәзәсендән әкертен туғры урамға сикерде [Акъегет, 1886, б. 56]; Чуқ шадландым ки, исламдан мәғлүмәте мәғыйшийә тәхсил идән (تحصيل ايدن) зат күрермен [Акъегет, 1886, б. 43] һ.б.;

ә) предмет яисә затның билгеле бер заманга карамаган процессуаль билгесен тасвирлаганда: Бу ханә үзе кечек булса да, тахтадан башы, анбары вә мөхкәм сарайлары сахибенең иҗтиһадлы, хезмәт сәвән (سون) адәм идегене күстәрерләр иде [Акъегет, 1886, б. 2]; Йә үлем түшәгендә йатан (يتان) бер кеше күрсәк, күземезә йәш, күңлемезә мәрхәмәт килер [Акъегет, 1886, б. 5]; Ғайсә Зурқолақов қунақлары бақырханәсендә булынан (بولنان) кәнде бүлмәсенә кертмәк эстәмеш иде [Акъегет, 1886, б. 47] һ.б.

*-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрне язучы сыйфатланмышлардан башка да файдалана. Бу очракта алар эш-хәрәкәтнең субъектын атап киләләр һәм үзләренә исем сүз төркеменә хас грамматик категорияләрнең күрсәткечләрен алалар. Романда исемләшкән *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләр түбәндәге рәвештә кулланыла:

а) баш килештә: Фәқәт шәкердләр ғад улынанлар (عد اولنانلر) дәһа қаты йапышдылар [Акъегет, 1886, б. 17]; Ғалиб улмақ эстәйәнләр (استيانلر) бу хәдисне ишедеп вә менла Хисаметдин илә мөбәхәсәйә тәқатләре йетешмәдегене фәһемләп сөкүтә мәҗбүр улдылар [Акъегет, 1886, б. 18]; Иғтиқад вә әфкәр мөштәрәк уланлар (مشترك اولنلر) арасында мөхкәм дустлық мәйдана килмәсе бәдиһидер [Акъегет, 1886, б. 29].

ә) иялек килешендә: Бу қычқырышмайы ишедеп зыйәфәтдә булынанларың (بولنانلرك) бәғзеләре чәйләрене оныдып, Бикбулат менланың шәкердләрендән хәйран қалдылар [Акъегет, 1886, б. 16].

Исемләшкән *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең язучы *ичүн* (ايچون) бәйлеге белән дә куллана: Бу мөсафирханә киләнләр ичүн (كلنلر ايچون) бүйүк бер ханәдән вә бер йинә артда кечек ханәдән ғибәрәт улып, сахибе Ғаббас әфәнде Биктимер уғлы бер төҗҗар иде [Акъегет, 1886, б. 9].

Исем фигыль урынында килгән *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрне язучы урын-вакыт килешендә куллана. Бу очракта алар җөмләдәге төп-эш хәрәкәтнең башкарылу вакытын ачыклап киләләр һәм аның белән бер вакыт яссылыгында башкарылган процессны белдерәләр: Хисаметдин менла туғры аңа қаршы варып кәчәндә (كچنده) әкертен бу сүзләре дийеп алды... [Акъегет, 1886, б. 21]; Ғаҗәибдер ки, әүwәл wақытларда менламыз қызы кәчеп кидәндә (كيده نده) күрсә дә, бик шад улыр иде [Акъегет, 1886, б. 21] һ.б.

Әсәрдә чыгыш килеше кушымчасын алган *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльнең *соңра* (صنكره) бәйлеге белән кулланылыш очрагы да теркәлде. *-андан соңра* конструкциясе җөмләдәге башка эш-хәрәкәтнең вакыт ягыннан башлангыч ноктасын белдерә: Хәнифә туташның менла кидәндән соңра (كيدندن صنكره) менланың артындан тиз ғаиб улмақындан Ғайниҗамал абыстай қызның менла илә тапышдықыны белә төшде [Акъегет, 1886, б. 68].

З. Бигиев әсәрләрендә *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләр шулай ук автор сөйләме белән бергә персонажлар сөйләмендә дә кулланыла. Мәсәлән:

Бер дәқиқа кәчдекдән соңра хадим килеп: «Әфәндем! Сезне күрергә эстәйән (استيان) адәмнең исеме – Иван Иванович Шубин», – диде [Бигиев, 1887, б. 10];

– Господин Ғабдуллин! Сез беләмесез бу эшдә шаһид улан (شاهد اولان) Ғабденнәсырны?

– Беләмен, бик йахшы беләмен, – дийү җаwаб вирде Ғабдуллин [Бигиев, 1887, б. 43–44];

Ғабдуллин Ғабденнәсыр әфәндейә қараб: «Энем, әгәр дә мәхкәмәдә күстәрән (كوستران) йазуығызны кичә бәңа йазып вирмәгән булса идең, Муса Салихов қәтелдә мәғйүб улмаенча, хәлас улыр иде...» [Бигиев, 1887, б. 48];

– ...Гизлеҗә бала туғдырмайа эстәйән (استيان) хатынлара йәрдәм қыламын. Ләкин сәне ниндәләйен хатын улдығыңны да белмимен [Бигиев, 1890, б. 35];

– Кем, ниндәй хатын қәтел қылған?

– Хәер, хайр, аны да мөғаййән белмим. Қазандан кидәр сәғәтдә генә ишетдем... Ләкин қәтел идән (قتل ايدن) хатынны бик җәмилә дип әйтделәр [Бигиев, 1890, б. 37].

Атрибутив позициядә килгән *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрне автор түбәндәге максатларда куллана:

а) предмет яисә затның үткәндә башкарылган эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен күрсәтү өчен: Ғыйззәтле укучы, Ғабдуллин мәхкәмәдә председательгә күстәрән (كوسترن) кәғәз ниндәләйен кәғәз идегене шимди анлағансыздыр [Бигиев, 1887, б. 48]; Окружной судда қәтелдә мәғйүб улан (معيوب الان) кешене нахақ ун сәнәлеқ каторжный хезмәткә хөкем идмешләр [Бигиев, 1887, б. 67]; Бу қартчық шәһәр өстенә чығып йөрмәдеге сәбәбдән, үткән кичдә улан (اولان) қәтелне вә Маһруйның шимди мәхбүсә улдығындан һич дә хәбәрдар дәгел иде [Бигиев, 1890, б. 27]; Ләкин қәтел идән (قتل ايدن) хатынны бик җәмилә диб әйтделәр [Бигиев, 1890, б. 37]; Йәтим, чарасыз, мескенлекдә қалмыш Ғабдулланың шу айаныч хәленә мәрхәмәт нәзары илә бақып, йәрдәм итмәгә қасд идән (قصد ايدن) татар Субаш қәрйәсендә дә, әтрафда да булынмады [Бигиев, 1908, б. 22]; Мозаффар хан ... 1277 сәнә һиҗрийәдә wафат улан (وفات اولان) Нәсрулла ханың баласыдыр [Бигиев, 1908, б. 77] һ.б.

ә) предмет яисә затның хәзерге заманга караган процессуаль билгесен белдерү өчен: Әфәндем,сезне күрергә эстәйән (استيان) адәмнең исеме – Иван Иванович Шубин [Бигиев, 1887, б. 10]; Әмма Ростовда тиҗарәт вә хезмәт идән (تجارة و حذمت ايده ن) кемсәмез қайтып килсә, ... биш wақыт намазы мәсҗедә килеп җәмәғәтлә әдә қылалар [Бигиев, 1890, б. 4]; Йәш ғомерне бушқа кичерергә ярамый дигән бу кеби қартчықлар вә йәш ғомерләрене бушқа кәчермәйән (كچرميان) бөйлә йәшләр дә аз дәгелдер [Бигиев, 1890, б. 16]. Гизлеҗә бала туғыран хатунлар ичүн туғырмайа мәхәл вирән (محل ويره ن) вә балалары тәрбийә қылан (تربيه قيلان) бөйлә қарт хатынлар Қазанда йуқ дәгелдер [Бигиев, 1890, б. 19] һ.б.

б) предмет яисә затның билгеле бер заманга карамаган процессуаль билгесен тасвирлаганда: Сез Муса Салиховның қатил идегенә дәләләт қылан (دلالت قيلان) шәйләр җәмғ қылдыңыз [Бигиев, 1887, б. 51]; Бәғзесенең нәсәбәт ата вә бабалары мәғлүм улмадығы ичүн бөйлә адәмләрә ихтилат идмәйән (اختلاط ايدميان) вә мәзһәбләре мәғлүм улмадығы ичүн хатын-қыз вирмәйән (ويرميان) адәмләр хата қылмыйлар [Бигиев, 1890, б. 51–52]; Урынларындан торып йөрмәйә мөқтәдир улан (مقتدر اولان) арестанткалар үлмеш арестантканың йанына килеп,... [Бигиев, 1890, б. 56]; ...шу вилайәтләрнең йирләрендә хасыйл улан (حاصل اولان) ашлық бәрәкәсе илә тәмам Русийә дәүләте тәрбийә улыныр [Бигиев, 1908, б. 15]; Йаурупа фабрикалары ғаҗиз улан (عاجز اولان) эшләре төрекмән хатыны садә әлилә хәзер идәр [Бигиев, 1908, б. 45] һ.б.

З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» әсәрендә *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең *wақыт* (وقت) сүзе белән кулланылып, җөмләдәге төп эш-хәрәкәт белән бер вакыт яссылыгында башкарылган процессны белдерү очраклары теркәлде. Автор *-ан wақыт* конструкциясен төп эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын тасвирлаганда файдалана: Мәзин хәзрәтләре сүзене бөйлә тәмам идән wақытда (تمام ایده ن وقتده) мулла мөсафирләрә хитабән... [Бигиев, 1890, б. 4]; Йағқуб Ғалийевнең үлесене ғарабәйә қуйып Ибраһим Ғалийевнең өенә алып кидән wақытда (کیدن وقتده) романымызның героинясе, ... политсәйә юлланмыш иде [Бигиев, 1890, б. 23]; Йуқ, йуқ, мәдрәсәйә киләң wақытда (کلان وقتده) бер дә андай нәрсәләрне белмәй иде [Бигиев, 1890, б. 49–50] һ.б.

Язучы әсәрләрендә *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрне сыйфатланмышларыннан башка да файдалана. Бу очракта алар эш-хәрәкәтнең башқаручыларын белдереп киләләр һәм үзләренә күплек сан, килеш кушымчаларын алалар. Текстларда исемләшкән *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең түбәндәге килешләрдә кулланылуы теркәлде:

а) баш килештә: Соңра керәнләр (کره نلر) артдағы софуфларға ултырышдылар [Бигиев, 1887, б. 37]; Хатынларымызның да арақы вә башқа мөскираты сәвәнләре (سوه نلری) йуқ дәгел [Бигиев, 1890, б. 6]; Қызларыңыз арасында, сөйләдәгем кеби, тәрбийә күрәнләре (تربیه کورنلری) улмаса да, хөсне җәмале илә әтрафда мәшһүр қызларың беренене мелла Ғабдулла ғақде никях идеп әвләнде [Бигиев, 1908, б. 28] һ.б.;

ә) иялек килешендә: Әнкәй, қызым, йидеш, йәрдәм қыл, дидекләре, ут-атәш эчендә йананларның (یاناڶلرنك) ағызындан Маһруйның қолағына ишеделмәйә вә күзенә күренмәйә башлады [Бигиев, 1890, б. 23–24]. Урта Асиядә, Мавәраэннәһердә сәяхәт идәнләрең (سیاحت ایدنلرڭ) иң мәшһүре венгр ғоләмасындан сәййах мәшһүр йәһүд Ақсақ Вамбери җәнабләредер [Бигиев, 1908, б. 11]; Қасыйм хәзрәтләр сәхабәдер; Сәед әл-Вөҗүд хәзрәтләренең җәсәде мөбарәкләрене ғоселдә хәзер уланларың (حاضر اولانلرڭ) бередер [Бигиев, 1908, б. 92] һ.б.;

б) юнәлеш килешендә: Мабәйенләрендә яхшы бай малдар кемсәнәләр күп, әмма шундалайын фәқир шәкердләрә яки башқа әмердә мохтаҗ вә йәрдәм лйазем уланлара (لازم اولانلره) инғам, ихсан вә йәрдәм қыланлары һич дә йуқ [Бигиев, 1890, б. 10]; Шу үзеңдән әғлә вә әдна уланлара (اعلی و ادنی اولان لره) бақып, инсаф вә намус қылмадың [Бигиев, 1890, б. 62]; Хикәйә сөйләйәнләрә (سویله ینلره) бурада мидах дәрләр имеш [Бигиев, 1908, б. 87] һ.б.;

в) чыгыш килешендә: Маһруйның атасы Ғали Wаһабов безем кеби абы хәйәт эчәнләрдән (اجنلردن) улмайып, бер мараза уғрайып, ике җомға миқдар хаста улып, фанидән бәқайа кәтде [Бигиев, 1890, б. 11].

Әсәрдә исемләшкән *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең *кеби* (كبى) бәйлеге белән кулланылу очрагы да теркәлде: Ниһайәтсез саран бәхил вә хасид кемсәнәләр улып, абы хәйәт эчәнләр кеби (اجنلر كبى) төн-көн җәлбе дөнйа мал артдырмақ қайғысында улып... [Бигиев, 1890, б. 10–11].

Автор *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрне *кеби* (كبى) бәйлеге белән алар исем фигыль мәгънәсендә килгәндә дә куллана. Бу очракта *-ан кеби* конструкциясе җөмләдәге башка эш-хәрәкәтнең ни рәвешле башкарылуын ачыклап килә: ...хезмәтче қартчықның сүзләрене вә тәклифене бер дә ишедмәйән кеби (ايشدميه ن كبى) улып, ... буынларыны қуәтләндермәк ичүн әүwәлге мәйханәйә тәвәҗҗеһләнде [Бигиев, 1890, б. 46–47].

Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәре өчен *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең кулланылышы хас түгел. «Әсма, яки Гамәл вә җәза» романында алар автор сөйләмендә атрибутив позициядә һәм исемләшкән хәлдә очрый. Атрибутив позициядә *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрне язучы түбәндәге очракларда куллана:

а) предмет яисә затларның үткәндә башкарылган эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен күрсәткәндә: Миладдан 381 сәнә мөқәддәм Этна шәһәрендә дөнйайа киләрәк 322 сәнә мөқәддәм wафат идән (وفات ايدن) мәшһүр бер философ вә хатиб иде [Фәхретдин, 1903, б. 6]; Қадим заманда тәдвал иделән (تدوال ايدلن) кечкенә ақ көмеш тәңкәгә истиғмал иделенер иде [Фәхретдин, 1903, б. 9]; Йақын қарендәшләрендән мәхрүм улан (محروم اولان) Әсманы аwылның иғтибарлы кемсәләрендән саналмақда улан Йосыф бабай тәрбийә итмәк улып ханәсенә алды [Фәхретдин, 1903, б. 45] һ.б.;

ә) предмет яисә затларның билгеле бер заманга карамаган процессуаль билгесен тасвирлаганда: Ғыйлем мәртәбәсене вә адәм мәртәбәсене белән (بيلن) адәм бу туғрыда асла бәхәс әйләмәз [Фәхретдин, 1903, б. 14]; Бичара бәндә!.. Бер дәқиқа эчендә бер-беренә зыд улан (ضد اولان) доғалары әйтмәкдәдер!.. [Фәхретдин, 1903, б. 44]; Бикбулат хәзрәт башқорд мәмләкәтендә беренче милек сахибе улан (ملك صاحبى اولان) Хикмәт хаҗи кийәwе улдығы хәлдә, ничүн бу қәдәр күп вә бай хатынлар алмайа мәҗбүр улды?.. [Фәхретдин, 1903, б. 101] һ.б.

Автор *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрне сыйфатланмышларыннан башка да куллана. Бу очракта алар процессның башкаручысын белдереп киләләр һәм үзләренә күплек сан, тартым, килеш кушымчаларын алалар. Әсәрдә исемләшкән *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең түбәндәге килешләрдә кулланылуы теркәлде:

а) баш килештә: Ләкин дөнйада ғайәт диққәт илә, хәтта ки илче улып йөрмәкдә улан затлара да аңлатмаз қәдәр мәғнәле сөйләүчеләр улдығы кеби, бунлары аңлаб җаwаб вирәнләр (جواب ويرنلر) дә вардыр [Фәхретдин, 1903, б. 43]; Зәйнүш абыстайның мажаралары вә хикәйәләре йалғыз бунлар улмай, бунлардан қызық вә бунлардан қурқынычлы уланлары (قورقنچلى اولانلرى) аз дәгелдер [Фәхретдин, 1903, б. 64]; Бунлар арасында ғайбәт сөйләмәк туғрысында ән җәсарәтле уланлары (جسارتلى اولانلرى) мөғәллимәнең ата вә анасы, нәсел вә қабиләсе мәғлүм улмадығындан, истидләл идәрәк ғайре мәшруғ сурәтдә дөнйайа килмеш улмасыны тәшхир идүчеләр иде [Фәхретдин, 1903, б. 92];

ә) иялек килешендә: Бере, без әшғари иғтиқадындамыз, әшғари иғтиқадында уланларың (اولانلرك) җөмләсе җәннәтлек, без дә җәннәтлек дия, арқасыны ыстинәгә сөйәп, күкрәгене кийереп йатмыш иде [Фәхретдин, 1903, б. 27]; Кәнделәре тәғлим вә тәрбийә илә мәшғүл улмадықлары хәлдә, буныңла мәшғүл улынанларың (مشغول اولانلرك) ғәмәлләрене интиқад вә мәсхәрә идәрәк йөрмәкдә улан затлар кәнде ғәмәлләрене зайығ итмәкдәләр вә башқаларың йулларына чоқыр қазмақдалардыр [Фәхретдин, 1903, б. 38];

б) юнәлеш килешендә: ...вә фәқәт wақытларында сарыф идәнләренә (صرف ايدنلرينه) дә бармағыны тешләб үкенер иде [Фәхретдин, 1903, б. 9]; Очраған wақытда йырақдан торып сәлам бирмәгәнләрә яки хөрмәт күстәрмәкдә қосурлық идәнләрә (قصورلق ايدنلره) бер wақытыны туры китереп җәзасыны вирер иде [Фәхретдин, 1903, б. 15]; Бинаән ғаләйһи ғаилә башлығы вә милләт анасы улан хатын буш wақытларында бунлар илә ғөмер кәчерер вә әдәби мәҗлесләр қорып, қул астында уланлара (اولانلره) хөсне әхлақ вә ғибрәт дәресләре сөйләр [Фәхретдин, 1903, б. 96].

Башка килешләрдә исемләшкән *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең бары тик аерым кулланылыш очраклары гына теркәлде:

а) төшем килешендә: Ләкин вексельләрең һичберендә имзадан башқа бер шәй улмадығындан, ән күп суммалы уланыны (صومالى اولاننى) адвокат да кәндесе исеменә йазып, унтуқуз биң тәңкәлеге Хәмидәйә

виреп, аны һәм бу кеби олуғ малдан мәхрүм әйләмеш иде [Фәхретдин, 1903, б. 57];

ә) урын-вакыт килешендә: Өч көн соңра килән мәктүбдә хасталығы ағыр вә бер һәфтә соңында киләнендә (كلننده) пәк ағыр, ниһайәт, өч көн соңра киләнендә (كلننده) wафат улдығы бәйан иделенде [Фәхретдин, 1903, б. 57].

Ф. Кәрими сәяхәтнамәләрендә *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләр шулай ук атрибутив позициядә һәм исемләшкән хәлдә очрыйлар. Биредә алар автор сөйләменең үзенчәлеге булып торалар. Атрибутив позициядә язучы *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрне түбәндәге очракларда куллана:

а) предмет яисә затларның үткәндә башкарылган эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен күрсәткәндә: Озатмаға килән (كلن) адәмләрең әл вә мәндил ишарәтләре дәхи чуға вармады күренмәз улды [Кәрими, 1902, б. 5]; Әшйамызы китерән (كتيره ن) хаммала үҗрәтене вирдек, күндәрдек [Кәрими, 1902, б. 64]; Риwайәтләрә күрә бунлар ханлар заманында Ләһстан үзәренә һөҗүм идән (هجوم ايدن) Қырым ғаскәренең алдан вармыш бер фирқасы улып, насылса да соңралары шурада қалмышлар вә поляк қызлары илә әвләнмешләр [Кәрими, 1908, б. 45]; [Кәрими, 1908, б. 93]; Шу wақытда истиғмал иделән (استعمال ايديلن) атәшле вә атәшсез харб аләтләренең... [Кәрими, 1908, б. 93] һ.б.;

ә) предмет яисә затларның билгеле бер заманга карамаган процессуаль билгесен тасвирлаганда: Түтүн эчелмәйән (توتون ايچلميان) вагона димәк улды [Кәрими, 1902, б. 61–62]; Килдегемезең өченҗе көне аквариум, йәғни хайwанаты бәхрия мөхафәзә иделән (محافظه ايديلان) музәйә вардық [Кәрими, 1902, б. 74]; 1 нҗе майа қаршы кичә, сәғәт 1 қарарларында, Қырым йарым адасыны қорыйа берләшдерән (برلشديره ن) «Перекоп» бәрзәхыны кәчеп, Қырым шәбһе җәзирәсенә кердек [Кәрими, 1908, б. 30]; Шәрқың тәмиз йөрәкле, халис иманлы, саф қалебле, садақәтле, итәғәт вә мәрхәмәтле, сада дил вә мөсафирпәрвәр адәмләрене сәвмәйән (سوميان) кеше һич йуқдыр [Кәрими, 1908, б. 46] һ.б.

Моннан тыш язучы атрибутив позициядә килгән *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрне предмет яисә затның хәзерге заман яссылыгына қараган процессуаль билгесен күрсәткәндә дә файдалана: Суқақларда омнибус, трамвай, арабаҗы велосипедчыларың вә йайан гизән (كزن) адәмең хәд вә хисабы йуқ [Кәрими, 1902, б. 76]; Бурада сатылан (صاتيلان) шәйләрең үзәренә Эйфель қаләсенең рәсеме дөшерелмешдер [Кәрими, 1902, б. 107]; Қаләнең тәпәсендән бақдықда «Сена»

нәһерендә гизән (كزن) пароходлар адәтә кечек бер қаек хәлендә күренийурлар [Кәрими, 1902, б. 108] һ.б.

Исемләшкән *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләрне язучы нигездә түбәндәге килешләрдә куллана:

а) баш килештә: Бунларың арасында эш илә гизәнләр (كزنلر) чуқ исә дә, эшсез гәзәнләр (كزنلر) дә йуқ дәгелдер [Кәрими, 1902, б. 34]; Ахунд әфәнденең нә димәк истәдегене аңламайанлар (آڭلامايانلر) йалғыз Оренбург илә Қазанда дәгелмеш,... [Кәрими, 1902, б. 35]. Рәһнамәнең бәйанына күрә бурада өч йөз адәмлек йир улып, шимдики хәлдә бурайа кермәк шәрәфенә наил уланлар (نائل اولانلر) илле бер имеш [Кәрими, 1902, б. 128]; Мөселманлардан ошбу туғрыларда бер-берене тәкфир идәнләр вар [Кәрими, 1908, б. 54]; Җөмлә хәзер булынанлар (حاضر بولنانلر) ихтирамән айаға қалқып мөнәҗәт бетдекдә... [Кәрими, 1908, б. 78]; Иштә шу сурәтдә «Тәрҗеман»ың кәндесендә һәм бәйан улындығы вәҗехлә нотық сөйләйәнләр (سويليانلر) арасында... [Кәрими, 1908, б. 78]; Шимди беләнләр (بيلنلر), аңлайанлар (آڭلايانلر) вә файда илә зарарны фарқ идәнләр (فرق ايدنلر) чуғалды [Кәрими, 1908, б. 83] һ.б.;

ә) иялек килешендә: Дәвам идәнләрең (دوام ايدنلرڭ) әксәре әҗнәби милләтләр улып, һәр тарафда французҗа, нимсәҗә мохавәрәләр ишеделмәкдәдер [Кәрими, 1902, б. 22]; Һәм дә бу йулда гәзәнләрең (كزنلرڭ) әксәре улдықҗа тәмиз вә кибар тоқымдан улыйур [Кәрими, 1902, б. 31]; Бу бинаның вә эчендәге ятанларың (ياتانلرڭ) ғәзәмәте инсана дәһшәт виририйур [Кәрими, 1902, б. 118]; Газета, әдәбийат вә ғомумилә матбуғаты җәдидәнең нәдән бахыс идегене, нә файдалары улдығыны вә нәйә хезмәт итдегене вә анларла мәшғүл уланларың (مشغول اولانلرك) кемләр улдығыны... [Кәрими, 1908, б. 69] һ.б.;

б) юнәлеш килешендә: Наполеоның хосусый тарихларыны вә аның хақында йазылмыш саир мәҗмуғалары уқыйанлара (اوقيانلره) буның нә қәдәр бүйүк бер сәйәси вә қаһарман улдығы мәғлүмдер [Кәрими, 1902, б. 118]; Бераздан берәр қаһвә вирделәр, соңра эстәйәнләрә (ايستينلره) чәй вирделәр [Кәрими, 1902, б. 180]; Ләкин «Тәрҗеман»ы уқымайанлара (اوقومايانلره) бер мәғлүмат вә уқыйанлара (اوقويانلره) бер тәхтер улмақ үзәрә бән шуны бурайа ғайнән нәқыль итмәге мөнасиб күрдем [Кәрими, 1908, б. 74]; Безем қалебләремездә ғолүм вә мәғәрифә мәхәббәт вә аңа хадим уланлара (خادم اولانلره) хөрмәт хисе, инсанийәт вә мәдәнийәтә мәйел арзусы уйғанмасына беренҗе сәбәб сезең хезмәт қәләмийәңездер [Кәрими, 1908, б. 80] һ.б.;

в) төшем килешендә: ...кәнде фикерләренә муафик хәрәкәт итмәйәнләре (حركت ايتميانلرى) дәрхал көферлек мөһере басып қурқытамыйурлар [Кәрими, 1908, б. 36];

г) чыгыш килешендә: Даха зийадә иқтидар сахибе уланлардан (صاحبى اولانلردن) Аурупа дарелмәғәрифләренә кидеп, берәр дөрле шәғбәи ғолүм дә кәсеб ихтисас идәнләр дә вардыр [Кәрими, 1902, б. 23–24]; Фәсады әхлақ анларда безем йәшел чапан астында гәзәнләрдән (گزه نلردن) әксик улса гәрәк [Кәрими, 1902, б. 179].

Госманлы төрек теле өчен хас булган *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең барысы өчен дә хас. Чыганакларда алар нигездә атрибутив һәм субстантив позицияләрдә киләләр һәм *-ган* үткән заман сыйфат фигыльләрнең грамматик синонимнары буларак кулланылалар, аерым очракларда *-учы, -а торган* хәзерге заман сыйфат фигыльләрен алыштырып киләләр.

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-ан* кушымчалы сыйфат фигыльләр шигъри әсәрләрдә, газета текстларында һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә кулланылалар [Юсупов, 2006, с. 110–111; Миннуллин, 2012, с. 196–197; Абдулхаков, 2007, с. 19–20]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар, ярым чәчмә ярым тезмә формада иҗат ителгән дастаннардан кала, бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норма, норма вариантлылыгының бер күрсәткече булып торалар.

*-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләр. *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләр иске татар әдәби теленең борынгыдан килгән традицион үзенчәлекләреннән санала. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында госманлы төрек теленең йогынтысы нәтиҗәсендә аларның кулланылыш даирәсе тагын да киңәя. Төрек телендә бу сыйфат фигыльләр зат яисә предметны үткәндә башкарылган эш-хәрәкәт буенча ачыклап киләләр [Кононов 1956, с. 472]. *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләр билгеле бер дәрәҗәдә татар телендәге *-ган* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләренең грамматик синонимнары булып торалар, ләкин, алардан аермалы буларак, абсолют үткән заманны белдерәләр, ягъни *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең заман мәгънәсе җөмләдәге төп эш-хәрәкәтнең заманына бәйле түгел. Моннан тыш сөйләм барышында аларның мәгънәсе нәтиҗәлелек төсмере белән дә баетылырга мөмкин.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы иске татар язма чыганакларында *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең атрибутив позициядә, исемләшкән хәлдә һәм исем фигыль мәгънәсендә кулланылуы күзәтелә. Аларның сыйфатланмышы урынында аннан аңлашылган эш-хәрәкәтнең субъекты, объекты, башкарылу урыны һәм вакыты мәгънәсендәге сүзләр килә. Әлеге сыйфат фигыльләр фигыль нигезенә *-мыш/-меш* (مش-) кушымчасы ялганып ясала: уқытмыш вә тәҗрибә итмеш (اوقوتمش و تجربه ایتمش) кешеләр [Акъегет, 1886, б. 3], раст килмеш (راست کلمش) дағ [Акъегет, 1886, б. 7], уқымыш (اوقومش) қыз [Акъегет, 1886, б. 11], вәғдәләнмеш (وعده لنمش) wақыт [Акъегет, 1886, б. 25], тақылмыш (طاقلمش) сәғәтләр [Акъегет, 1886, б. 37], wақыйғ улмыш (واقع اولمش) эш [Бигиев, 1887, б. 4], қанға буйалмыш (بویالمش) мәқтүлә хатын [Бигиев, 1887, б. 5], күстәрелмеш (کوسترلمش) йиргә [Бигиев, 1887, б. 11], Қазанға кидмеш (کیدمش) Ғабделғафур [Бигиев, 1890, б. 7], өйләнмеш (ایولنمش) кемсәнә [Бигиев, 1890, б. 12], ачылмыш (آچلمش) қапыдан [Бигиев, 1890, б. 30], тәхриб улынмыш (تخریب اولنمش) асары мәдәнияте [Бигиев, 1908, б. 9], хөкүмәт сөрмеш (حکومت سورمش) бер дәүләтең [Бигиев, 1908, б. 40], балчықдан йасалмыш (یاصالمش) бүйүк қурған [Бигиев, 1908, б. 61], бина иделмеш (بنا ایدلمش) бер шәһәр [Кәрими, 1902, б. 7], күндәрелмеш (کوندرلمش) махсус адәм [Кәрими, 1902, б. 11], гүзәл қадифәләр илә дүшәнмеш (دوشنمش) кечек бер одайа [Кәрими, 1902, б. 65], мәйдана китерелмеш (میدانه کتیرلمش) тимер юллара [Кәрими, 1908, б. 11–12], табиғәт тарафындан вирелмеш (ویرلمش) ақылыны [Кәрими, 1908, б. 13], тәрҗемә иделмеш (ترجمه ایدلمش) берқач әсәрләре [Кәрими, 1908, б. 21–22], татар ханларындан қалмыш (قالمش) әсәр [Фәхретдин, 1899, б. 3], мәктәбдә үткәрмеш (اوتکارمش) көнләремнең [Фәхретдин, 1899, б. 54], зикер иделмеш (ذکر ایدلمش) яқшәнбә мәктәбләре [Фәхретдин, 1899, б. 70], күрмеш (کورمش) вә күрмәмеш (کورممش) дөшләрене [Фәхретдин, 1903, б. 32], бәйан иделмеш (بیان ایدلمش) йазу [Фәхретдин, 1903, б. 57], асылмыш (آصلمش) бер қапчық [Фәхретдин, 1903, б. 61] һ.б.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләр автор сөйләмендә һәм атрибутив позициядә генә кулланылалар. Атрибутив позициядә *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләр сыйфатланмышларының үткән заманга караган процессуаль билгесен белдереп киләләр: Әмма Хисаметдин мәктәбендә уқытмыш вә тәҗрибә итмеш (اوقوتمش و تجربه ایتمش) кешеләр қарт менланың буш сүзләренә инанмайып, Хисаметдин менлайы Камал рәғбәтдә тотарлар иде [Акъегет, 1886, б. 3]; Йулында

раст килмеш (راست كلمش) бер дағы менла менәр икән, артдан ике ат қушылмыш бер ғарәбә йетешде [Акъегет, 1886, б. 7]; Вәғдәләнмеш (وعده لنمش) wақыт йитешде [Акъегет, 1886, б. 25]; Ләкин бердән ишеделмеш (ايشدولمش) ики-өч мылтық садәсе қадынлар сүзене кисде [Акъегет, 1886, б. 52]; Килмеш (كلمش) қунақ бер аwылдан белеш қадындыр [Акъегет, 1886, б. 66] һ.б.

*-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләрне автор зат яисә предметның нинди дә булса эш-хәрәкәтнең башкарылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзенчәлеген тасвирлаганда да файдалана: Суланмыш (صولانمس) «Тәрҗеман»ы исә софрайа быpақды [Акъегет, 1886, б. 7]; Хәнифә туташ үзе дә уқымыш (اوقومش) қыз иде [Акъегет, 1886, б. 11]; Қарт қадынының бу көн икмәк пешермәгене бераз онланмыш (اونلنمش) чабуы күстәрер иде [Акъегет, 1886, б. 51] һ.б.

Әсәрдә исемләшкән *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльнең бары бер генә кулланылыш очрагы теркәлде: Утырмышларың (اوتورمشلرك) бәғзеләре менла илә сохбәткә керешделәр [Акъегет, 1886, б. 10].

З. Бигиев әсәрләрендә *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләр нигездә атрибутив позициядә, сирәк очракларда исемләшкән хәлдә дә очрыйлар. Биредә алар автор сөйләменең үзенчәлеге булып торалар. Аерым очракларда язучы аларны персонажлар сөйләменә дә кертеп җибәрә. Мәсәлән:

Тәфтишчеләр номерләргә кердекләрендән соңра: «Үлтерелмеш (اولترلمش) хатын қайсы номердә?» – дийү номерләр сахибенә тәфтишчеләрнең берсе сөаль қылдығында,... [Бигиев, 1887, б. 4–5];

Шу сүзләрдән йалан буйақчылар қурықды исәләр дә, Мәмәт нәхү хәүф күстәрмәенчә:

– Хайр, без иртә өстендә килмеш (كلمش) буйақчылар дәгелмез... [Бигиев, 1890, б. 71].

Әсәрдә *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләрне язучы атрибутив позициядә түбәндәге очракларда куллана:

а) предмет яисә затның үткән заманга караган процессуаль билгесен тасвирлаганда: ...иртә намаз wақытында Әхмәди бай, Ниғмәтулла әфәнде, Ғабденнасыр әфәнде, господин Андреев Муса әфәнденең хәбес қылынмыш (حبس قلنمش) бүлмәсенә кермешләр [Бигиев, 1887, б. 34]; Господин Шубин господин Иванов киткәч, Ивановдан ишедмеш (اشدمش) хәбәрне господин Андреевқа барып сөйләде [Бигиев, 1887, б. 56]; Йағқуб әфәнде Мостафа килтермеш (كلترمش) мәктүбе уқып, аҗәлә қылып ивдән кәтде [Бигиев, 1890, б. 15]; Қартчығның бу

сүзләре Маһруйның Йагҗуб Ғалийев өстенә салынмыш (ثالنمش) җайнар суындан зийадәрәк җайнар күренде Җиһангир әфәндейә [Бигиев, 1890, б. 15]; Шу җәдәр җәмәғәте мескенлек, бичаралыҗ хәленә дөшермеш (دوشورمش) залимләрең бере безем әлдә иде [Бигиев, 1908, б. 20]; Шу Дербенд шәһәре wаҗыты илә Ширванда хөкүмәт сөрмеш (حكومت سورمش) бер дәүләтең пайтәхете иде [Бигиев, 1908, б. 40] һ.б.;

ә) зат яисә предметның нинди дә булса эш-хәрәкәтнең башкарылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән сыйфатын белдерү өчен: Идән уртасына җанға буйалмыш (بويالمش) мәҗтүлә хатын йығылмыш [Бигиев, 1887, б. 5]; Биш-ун дәҗиҗа эчендә җайнамыш (قاينمش) самаварны Ғабденнасыр әфәнденең одасына – номеренә килтермеш [Бигиев, 1887, б. 54]; Маһруйның атасы Ғали Ваһабов – ғаләтдәвам бәлдәи Җазанда иҗамәт вә алыш-виреш тиҗарәт идеп, хили күп мал, аҗча җазанмыш (قضانمش) вә алтмыш биш йәшләренә ирешмеш (ايرشمش) йахшы, мөттәҗый вә сәхи адәмдер [Бигиев, 1890, б. 7]; Ибраһим Ғалийев утыз биш йәшендә вә өйләнмеш (ايولنمش) кемсәнә улып, ике балайа ата вә олуғ юрист мәккәр вә мөфәттин бер кемсәнәдер [Бигиев, 1890, б. 12]; Чыңғыз әлендә тәхриб улынмыш (تخريب اولنمش) асары мәдәнийәте ихйа итмәйә сәғый итде [Бигиев, 1908, б. 9]. Бохара, Пекин шәһәре кеби, балчыкдан ясалмыш (ياصالمش) бөек җурған илә ихата улынмышдыр [Бигиев, 1908, б. 61] һ.б.

Исемләшкән *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләр З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романында һәм «Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» сәяхәтнамәсендә очрый: Ғабделғафурны озатмайа килмешләрнең (كلمشلرنك) бере... [Бигиев, 1908, б. 5]; Хаста йә зәғиф улмышларың (ضعيف اولمش لارڭ) әксәре хезмәте ғаскәрийәйә алындылар [Бигиев, 1890, б. 25]; Әлендә силах улдығы хәлдә шәһадәт дәрәҗәсенә вармышларың (وارمشلارڭ) ғадде тәхминән йегерме биң җәдәр иде [Бигиев, 1908, б. 54].

Шуның белән бергә әлеге әсәрләрдә *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең *кеби* (كبى) бәйлеге белән кулланылу очраклары да теркәлде. *-мыш кеби* конструкциясен язучы җөмләдәге төп эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен тасвирлаганда файдалана: Йалан буйаҗчылара раст килмеш арестантның әйтдеге сүзләрене ишедмәмеш кеби (ايشدممش كبى) улып, ... җапыйа тәвәҗҗеһ җылып бармайа дәвам итделәр [Бигиев, 1890, б. 68]; Видағ сәламләре соңында, гүя юлчыларың җалебләренә фираҗ әләме истила итмеш кеби (استيلا ايتمش كبى), пароходымызда бер сөкүн пәйда улды [Бигиев, 1908, б. 2]; Мөхарәбә

соңында Күктәпәдә кыямәт купмыш кеби (قيامت قوپمش كبى) улды... [Бигиев, 1908, б. 55] һ.б.

Р. Фәхретдин романнарында *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләр автор сөйләмендә һәм атрибутив позициядә генә очрыйлар. Әсәрләрендә *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләрне язучы атрибутив позициядә түбәндәге очракларда куллана:

а) предмет яисә затның үткән заманга караган процессуаль билгесен тасвирлаганда: Бу исә тәҗрибә иделмеш (تجربه ايدلمش) бер шәйдер [Фәхретдин, 1899, б. 24]; Чөнки белмәйдер идем, мәктәбдә үткәрмеш (اوتكارمش) көнләремнең һәр сәгатене тәхсилдә үткәрмәдем [Фәхретдин, 1899, б. 54]; Буның эше ишанлар мәнакыйбләрене сөйләмәк вә кәрамәтләрене риwайәт итмәк вә аңа тәбган кәнденең күрмеш (كورمش) вә күрмәмеш (كورممش) дөшләрене хикәйәт әйләмәк иде [Фәхретдин, 1903, б. 32]; Җәмал вә гүзәллеге йирендә, сөйләшүе ләззәтле, кәндесе дә гайәт дә җазибәле улдыгындан, тиз көндән бундан элек китмеш (كتمش) деләнче кызлар урынына бу һәм кидәчәк иде!.. [Фәхретдин, 1903, б. 66]; Хатын да байың вирмеш (ويرمش) гакылына вә үгрәтмеш (اوكرتمش) дәресенә күрә Салих байга варып, йалгыз бер йәтим кызы илә урамда калдыгыны сөйләде [Фәхретдин, 1903, б. 75] һ.б.;

ә) зат яисә предметның нинди дә булса эш-хәрәкәтнең башкарылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән сыйфаты турында сөйләгәндә: Сәламәтләнмеш (سلامتلنمش) хатынлар чыкып, анлар йиренә йаңалар килеп-кидеп торырлар [Фәхретдин, 1903, б. 68]; Айакларында аппак ойык, өсләрендә йәшел материядән күлмәк, ак киндердән ал йапма, башларында кызыл хәтфә (катыйфә), өстенә чикмеш (چيكمش) калпак, аның өстендә зәңгәр төсдә кечкенә шәл салынмышдыр [Фәхретдин, 1903, б. 88]; Бунлар өммәт эчендә бер черемеш (چوررومش) әгзә кеби улырлар, бунлар сәбәбендән милләтең байлыгы йаз көне кары кеби эрер кидәр [Фәхретдин, 1903, б. 95].

Ф. Кәрими сәяхәтнамәләрендә дә *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләр автор сөйләмендә һәм атрибутив позициядә генә очрый. Әсәрләрендә *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләрне язучы атрибутив позициядә түбәндәге очракларда куллана:

а) предмет яисә затның үткән заманга караган процессуаль билгесен тасвирлаганда: Дөнйада бу замана кәдәр иҗат иделмеш (ايجاد ايدلمش) нә кәдәр машина вә аләт вар исә, бу музәдә кечек бер микйасда һәпсенең берәр моделе мәүҗүд улып, аның илә насыл эшләндеге күстәрелмеш иде [Кәрими, 1902, б. 132]; Бөтен хәйәтең кичмеш (كچمش)

дәқиқалары күз уңына килийур [Кәрими, 1902, б. 139]; ...табиғәт тарафындан вирелмеш (ويرلمش) ақылыны да ғаиб идеп, бер адәм янына варып өч-биш кәлимә сүз сөйли алмазлық дәрәҗәдә ашағы қалмышдыр [Кәрими, 1908, б. 13–14]; Ниқах бәғдендә ир улан адәм шул әүwәлдән қуйылмыш (قويولمش) шартлары йиренә китермәдеге кеби, әгәр эстәрсә, хатын үзене ирендән талақ идеп китмәгә мохтардыр [Кәрими, 1908, б. 23] һ.б.;

ә) зат яисә предметның нинди дә булса эш-хәрәкәтнең башкарылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән сыйфаты турында сөйләгәндә: Самара бәлдәсе Волга нәһеренең сул сахиленә бина иделмеш (بنا ايدلمش) бер шәһәр улып, сиксән биң қәдәр нөфусы хавидер [Кәрими, 1902, б. 7]; Самарадан хәрәкәт бәғдендә өйләдән соңра сәғәт алтыларда Волга нәһере үзәренә қорылмыш (قورلمش) тимер күпердән кичтек [Кәрими, 1902, б. 7]; Ялғыз Оренбургда Хөсәйеновлар һиммәте илә ислах иделмеш (اصلاح ايدلمش) бер мәдрәсәдән азыҗық мәғәриф қуқысы килмәкдәдер [Кәрими, 1908, б. 7]; Тәғлим вә тәрбийә күрмеш (تعليم و تربيه كورمش) мөселман хатын вә қызлары һәр нә қәдәр ачық гизсәләр дә,... [Кәрими, 1908, б. 57] һ.б.

Иске татар әдәби теленең традицион үзенчәлекләреннән саналган һәм угыз телләре өчен хас булган *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләре XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы иске татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең барысында да теркәлде. Язма чыганакларда *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләр билгеле бер дәрәҗәдә *-ган* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләрнең грамматик синонимнары буларак кулланылалар, ләкин, алардан аермалы буларак, абсолют үткән заманны белдерәләр. Текстларда алар нигездә автор сөйләмендә һәм атрибутив позициядә генә теркәлделәр.

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-мыш* кушымчалы сыйфат фигыльләр чәчмә формада иҗат ителгән дастаннарда, шигъри әсәрләрдә, газета текстларында һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә кулланылалар [Шамарова, 1990, с. 78; Юсупов, 2006, с. 113; Миннуллин, 2012, с. 195–196; Абдулхаков, 2007, с. 20]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норма, норма вариантлылыгының бер күрсәткече булып торалар.

*-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр. *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр иске татар әдәби теленең борынгыдан килгән традицион

үзенчәлекләреннән саналалар. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында госманлы төрек теленең йогынтысы нәтиҗәсендә аның кулланылыш даирәсе тагын да киңәя. Төрек телендә алар зат яисә предметны хәзерге заман яссылыгында яисә үткәндә башкарылган эш-хәрәкәт буенча ачыклап киләләр, ләкин аларның заманы җөмләдәге төп эш-хәрәкәтнең заманы белән билгеләнә. [Кононов 1956, с. 438–439]. *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр билгеле бер дәрәҗәдә *-ган* һәм *-мыш* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләрнең грамматик синонимнары булып торалар, ләкин, алардан аермалы буларак, *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр атрибутив позициядә дә эш-хәрәкәтнең кайсы затка караганлыгын күрсәтә торган тартым кушымчалары белән бергә кулланылалар. Шул сәбәпле аларның сыйфатланмышы урынында эш-хәрәкәтнең субъектын белдерә торган сүзләр килә алмый. Моннан тыш *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр өчен *-ган* һәм *-мыш* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләрендә күзәтелгән нәтиҗәлелек мәгънә төсмере хас түгел.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы иске татар язма чыганакларында *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр атрибутив позициядә һәм исем фигыль мәгънәсендә очрыйлар. Әлеге сыйфат фигыльләрнең сыйфатланмышлары урынында нигездә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең объекты, урыны һәм вакыты мәгънәсендәге сүзләр килә. Алар фигыль нигезенә *-дық/-дек* (-دوق-/-دوك) кушымчасы ялганып ясалалар: дидегемез (ديدوكمز) гимназист [Акъегет, 1886, б. 8], мөсафирлек ханәйә кердеге (كرديكى) әснада [Акъегет, 1886, б. 10], йаздығымыз (يازديغمز) Хәнифә [Акъегет, 1886, б. 19], ғыйбадәт қылдығымыз (عبادت قيلديغمز) мәхәлдә [Бигиев, 1890, б. 4], қазанлыларның йөрдеге (يورديكى) урамлар [Бигиев, 1890, б. 15], Ибраһим әфәнденең бойырдығы вә әйтдеге (بيورديغى و ايتديغى) сүзләре [Бигиев, 1890, б. 29], сезнең күстәрдегеңез (كوسترديگڭز) шу айаныч [Бигиев, 1908, б. 18], ишетдегем (ايشتديگم) хикәйәләр [Бигиев, 1908, б. 37], бәнем булындығым (بولنديغم) йир [Бигиев, 1908, б. 43], бақдығымыз (باقديغمز) рәхбәрдә [Кәрими, 1902, б. 17–18], йаздықлары (يازدقلرى) әсәрләрене [Кәрими, 1902, б. 37], вардығымыз (وارديغمز) ақшам [Кәрими, 1902, б. 37], Оренбургдан хәрәкәт итдегемез (حركت ايتديكمز) көнең [Кәрими, 1908, б. 8], Самарадан алдығымыз (آلديغمز) газеталары [Кәрими, 1908, б. 12], сурдығы (صورديغى) сөальләрендән, вирдеге (ويرديكى) җаwабларындан [Кәрими, 1908, б. 16], Қазанға килдегем (كيلدكم) йылда [Фәхретдин, 1899, б. 6], суыны эчдегем (سوينى ايچدكم) вә ниғмәтене

йидегем (نغمتینی ییدکم) вә hawасыны суладығым (هواسینی سولادیغم) Қазанны [Фәхретдин, 1899, б. 8], бунларның булындықлары (بولندقلری) урын [Фәхретдин, 1899, б. 17], исемләрене йад итдегемез (یاد ایتدکمز) вилайәтләрнең [Фәхретдин, 1903, б. 4], бунларың вирдекләре (ویردکلری) дәвалар [Фәхретдин, 1903, б. 29], сурдығың (صورردیغك) шәйләр [Фәхретдин, 1903, б. 77] h.б.

Мәгърифәтче язучылар *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләрне, автор сөйләмендә куллану белән бергә, персонажлар сөйләменә дә кертеп җибәрәләр:

...

– Бәли туғры хәбәр, – җаwаб вирде Хисаметдин менла.

– Бәлки туғры, ама хәбес иделмәсенә сез сәбәбҗе улдығыңыза (سببجی اولدوغکزه) без hич инанмыйурыз [Акъегет, 1886, б. 15];

...Һәр нә қәдәр Хисаметдин менла бөйлә шәкердән илә сүзләшмәк эстәмәде исә дә, ләкин кяфер эше дәнилән сүзләренә чыдамайып бөйлә җаwаб вирде:

– Бунда нә вар әфәнделәр? Бән хәбес итдердегеме (حبس ایتدردوکمی) hич инкяр итмәзмен, бән хәбес итдердем. [Акъегет, 1886, б. 16];

...

Судебный следователь бу тариқа тәфтиш қылмаға шөруғ қылды:

– Сез, бу хатынның үтерелдегене (اولترولدوکنی) нә тариқа белдегез?

Хадимә бу тариқа жаwабқа шөруғ қылды:

– Бән сабахда хезмәт илән йөрдегемдә (یوردوکمده) бу номер янындан узып бардығымда (باردوغمده), бу номер ишегене яртылап ачық күреп, ни булса хезмәт йуқмы икән дийү, номерәйә кердегемдә (کردوکمده), бу хатынны бу кәйфийәтдә күреб, бик хәүфләндем. Хәтта номердән нә тариқа чықдығымны (چقدوغمنی) да белмәймен [Бигиев, 1887, б. 5–6];

...

– Җинайәтле улып тәфтиш вә хөкем хозурында улдығың (اولدیغنك) вармы?

– Йуқ

– Бик йахшы, менә сән Йағқуб Ғалийевне қәтел қылдығың (قتل قیلدیغنك) сәбәбдән без сәне тәфтиш өчен туғры вә ғадәләтле улан хөкем хозурына дәғwәт қылдық. Хәммам хуҗасы вә хәммам хадимләренең шәhадәт вирдекләре илә (شهادة ویردوکلریله) сәнең Йағқуб Ғалийевне қәтелең мөсбәт улды [Бигиев, 1890, б. 24–25];

...

– Сезең хамилә улдығыңызы (حامله اولدغنكزى) вә вәзғы хәмелеңезне әйтдегеңез (ايتديغنكز) акушерқайа мағада белән кеше варму? – дийү следовательнең сөаленә Маһруй:

– Хайр, мәнем хамилә улдығымдан (حامله اولديغمدن) вә бала туғдырдығымдан (توغدردوغمدن) мәзкүр акушерка-қартчықға мағада кемсә хәбәрдар дәгел... [Бигиев, 1890, б. 25–26].

Аерым очракларда авторлар *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләрне бер җөмлә эчендә бер-бер артлы кулланалар һәм әлеге алым күпмедер дәрәҗәдә сөйләмне җанландыра торган стилистик чара максатын үти: Бу сөальдән соңра Маһруй, бер миқдар тәфәккер қылып вә йөзенә хөмрәт-қызыллық ... килмәйенчә, зәүҗе Җиһангирнең Сибирийайа китдегендән соңра (كتدوكندن صنكره) бер ай бушқа кәчергән ғөмерендән башлаб, Йағқубла беренче дәфға нә тариқ вә нә йирдә күрешдегене (كوروشدوكنى) вә әүwәл күрешдекдән соңра (كوروشدوكدن صنكره) йиде ай бушқа кичермәйән ғөмерене тәфсыйлән вә нә wақытда хамилә улдығыны (حامله اولديغنى) вә йиде ай кичкәч, Йағқубла мабәенләрендә зоһур идән намәхәббәт вә салқынлықны вә соңра ике ай миқдар берберене күрмәдекләрене (كورمدوكلرنى) вә мәғлүмеңез қартчық ивендә ир уғлан вөҗүдә килтердегене (وجوده كلتردوكنى) вә баланың тәрбийәсе өчен Йағқубдан ақча алмақчы улып, қартчығның мәслихәте илә Йағқуб Ғалийевкә хат йазып, қартчықдан ирсал қылдығыны (ايرسال قيلدوغنى) вә Йағқубла күрешеп, хәммамда улан сүз вә фигыльләрене – һәрқайусыны тәфсыйлән бәйан қылды [Бигиев, 1887, б. 25].

М. Акьегетнең «Хисаметдин менла» романында *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр атрибутив позициядә һәм исем фигыль мәгънәсендә кулланылалар. Атрибутив позициядә автор аларны сыйфатланмышларның үткән заманда башкарылган эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен тасвирлаганда файдалана: Бәнем иғтиқадыма күрә тәғриф итдегең (تعريف ايتدكنك) олуғ ғарәб йиренең хараб улмасына сәбәб хәлифәләренең исламийәт күстәрдеге (كوستردیكی) тарыйкдан чықмақларыдыр [Акъегет, 1886, б. 23]; Әмма вирмәсәләр, Алла бәңа вирдеге (ويرديكی) ирадәмнең қуәтенә һичбер шәй мөқабәлә идәмәз [Акъегет, 1886, б. 40]; Ғали бай илә Бикбулат менланы туй җәмғыйәте қайтқач, шәһәрә вармаға дәwам итдекләре (دوام ايتدوكلرى) хәлдә қалдырдық [Акъегет, 1886, б. 59] һ.б.

Әсәрдә *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең *әсна* (اثنا), *wақыт* (وقت) сүзләре белән кулланылу очраклары да теркәлде. Бу вакытта алар төп эш-хәрәкәт белән бер вакыт яссылыгында башкарыла торган

процессны белдереп киләләр. Әсәрдә *-дык әсна//wақыт* конструкциясе җөмләдәге башка эш-хәрәкәтнең үтәлеш вакытын күрсәткәндә кулланыла: Менла мөсафирлеқ ханәйә кердеге әснада (كرديكى اثناده) Хәнифә туташ мәзкүр кечек бүлмәдә ойық туқып утырыр иде [Акъегет, 1886, б. 10]; Вә узып китдеге wақыт (كتديكى وقت) йәш җегет әйләнеп бақдықда, мәрқүмә шәкәр иренләрене вә энҗе дешләреене күстәреп көлеп алды [Акъегет, 1886, б. 20] һ.б.

Исем фигыльләр урынында килгән *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр үткәндәге яисә хәзерге заманда дәвамлы рәвештә башкарыла торган, аерым очракларда нинди дә булса заманга карамаган эш-хәрәкәтне атап киләләр. Язучы аларны түбәндәге рәвештә файдалана:

1) баш килештә: Йөзендән дәрин фикерә далдығы (دالديغى) беленер [Акъегет, 1886, б. 3]; Бу әхwәлдән мәдәнийәтемезең ноқсаны вә әхлақымызың алчақ дәрәҗәдә улдығы (اولديعى) аңлашылыр [Акъегет, 1886, б. 6]; Шәһәр тротуарларында йөрегән адәмләр һәрwақыт чуқ булындығы (بولندوغى) мәғлүмдер [Акъегет, 1886, б. 20–21];

2) юнәлеш килешендә: Бәлки туғры, әмма хәбес иделмәсенә сез сәбәбҗе улдығыңыза (سببجى اولدوغكزه) без һич инанмыйурыз [Акъегет, 1886, б. 15]; Инглиз кеби кәсепкәр улмадықымыза (اولمادقمزه) сәбәб кәзалик үземезмез [Акъегет, 1886, б. 22]; Алтын уқа илә йарашдырылмыш тақыйасы вә алтын сәғәтләре малдар вә олуғ бәкләрдән идегенә (ايدوكنه) бер дәлил кеби күрелерләр иде [Акъегет, 1886, б. 29];

3) төшем килешендә: Бу ханә үзе кечек булса да, тахтадан башы, анбары вә мөхкәм сарайлары сахибенең иҗтиһадлы вә хезмәт сәвән адәм идегене (ايدكنى) күстәрерләр иде [Акъегет, 1886, б. 2]; Менланың кердегене (كيردوكنى) белеп вә бер күрмәк эстәп, Хәнифә туташ эшене қуйып,... [Акъегет, 1886, б. 10]; Бән хәбес итдердегеме (حبس ايتدردوكمى) һич инкяр итмәзмен, бән хәбес итдердем. [Акъегет, 1886, б. 16];

4) чыгыш килешендә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен тасвирлаганда: Әмма чуқ адәм менлайы йахшы белмәдекләрендән (بيلمدوكلروندن) сәвмәзләр иде [Акъегет, 1886, б. 3]; Вә бу ике йәш юлҗы мөсахәбәт дәвам итдегендән (دوام ايتدوكندن) бер-берсенә хайлиҗә ярадылар [Акъегет, 1886, б. 8]; Исламы сәвдегемдән (سودكمدن) пулисәйә алдырдым [Акъегет, 1886, б. 16];

5) урын-вакыт килешендә башка эш-хәрәкәтнең үтәлеш вакытын конкретлаштырганда: Ханәйә яқынлашдықда (يقينلشدوقده) қыз сарай тарафына бақып вә бердән менланы күреп, ойалдығындан көлде вә тиз шәле илә қапланды [Акъегет, 1886, б. 10]; ...анчақ бер Хисаметдин

менла бик олуғламаз вә раст килдекдә (راست كلدوكده) кәндесене Ғали байға мөсәви кеби тотар [Акъегет, 1886, б. 14]; Вә узып китдеге wақыт йәш җегет әйләнеп бақдықда (باقدقده), мәрқүмә шәкәр иренләрене вә энҗе дешләрене күстәреп көлеп алды [Акъегет, 1886, б. 20].

Әсәрдә *-дық* формасының *соңра* (صكره), *илә* (ايله), *күрә* (كوره) бәйлекләре белән кулланылу очраклары да теркәлде. *Соңра* бәйлеге белән *-дық* формасы чыгыш килешендә кулланыла. Әлеге конструкция җөмләдәге башка эш-хәрәкәттән алда башкарылган процессны белдерә һәм билгеле бер дәрәҗәдә *-гач* кушымчалы хәл фигыльләрне алыштырып килә. Автор аңа икенче эш-хәрәкәтнең вакыт ягыннан башлангыч ноктасын күрсәткәндә мөрәҗәгать итә: Җомға намазыны уқыдықдан соңра (اوقودقدن صنكره) Хисаметдин менла атны чанайа йигеп, бәғзе кирәк шәйләр алмақ ичүн шәһрә йулланды [Акъегет, 1886, б. 7]; Бу мәктүбендә Хәнифәйә җаwабы ичүн тәшәккер итдегендән (تشكر ايتدوكندن صنكره) соңра ғашыйқанә сәчелмеш сүзләре арасында иғлан итде ки, Хәнифә ханым бер хәдисәйә хәзерләнсен [Акъегет, 1886, б. 26]; Сибғатулла әфәнде исә атасы илә хәбәрләшдекдән соңра (حبرلشدكدن صكره) үлек кеби ағарып, қайғы вә әфкяр дәрйасына батды [Акъегет, 1886, б. 54].

Әлеге мәгънәдә автор *-дығы илә* конструкциясен дә куллана, ләкин бу очракта ике эш-хәрәкәт арасындағы вакыт аралыгы кыскарак була: Әмма қыш кичеп, илк бахар, йәғни йаз башы ачылдықы илә (آچلدقى ايله) Хисаметдин менланың сурәте мәғыйшәте бераз тәбдил улды [Акъегет, 1886, б. 19]; Нурлы йөзеңе әүwәл күрдегем илә (كوردوكم ايله) вөҗүдем мөтәәсир улды [Акъегет, 1886, б. 24]; Хәнифә туташ Хисаметдин менладан ғайрейә йар улмаяҗағыны белдердеге илә (بيلدرديكى ايله) Шәмсеқамәр абыстай туйны тиз қылмаға ғайрәт итде [Акъегет, 1886, б. 54–55].

*Күрә* бәйлеге белән *-дық* формасы юнәлеш килешендә кулланыла: Мәктүбеңездән аңлашылдығына күрә (آكلاشلديغنه كوره) мәхәббәт вә ғыйшқыңызы ибраз әйләмеш улсаныз да, мәзкүр ғыйшқыңыза әмнийәт илә бақмақ мөнасиб дәгелдер, зан идәрем [Акъегет, 1886, б. 25].

З. Бигиев әсәрләрендә *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр атрибутив позициядә һәм исем фигыль мәгънәсендә кулланылалар. Атрибутив позициядә автор аларны сыйфатланмышларның үткән заманда башкарылган эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен тасвирлаганда файдалана: Господин Андрейевнең бишенче бабда йаздығымыз (يازدوغومز) мөшаwәрәсендән соңра өч-дүрт көн кәчкәч,... [Бигиев, 1887, б. 30]; ...Ибраһим әфәнденең бойырдығы вә әйтдеге (بيورديغى و ايتديغى)

сүзләре йазмайа башлады [Бигиев, 1890, б. 29]; Қартчығның йаздығы (يازديغى) кәғәзе Ибраһим Ғалийев арыслан ғайрәте илә қулына алып кесәсенә қуйдығы wақытда... [Бигиев, 1890, б. 29]; Сезнең күстәрдегеңез (كوسترديگڭز) шу айаныч бездә ғомуми дәгелдер [Бигиев, 1908, б. 18]; Волгин кеби бер русдан ишетдегем (ايشتديگم) хикәйәләр дә қальбемә бүйүк бер рәхәтсезлек вирмеш иде [Бигиев, 1908, б. 37] һ.б.

Текстларда *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең *wақыт* (وقت) һәм *сәбәб* (سبب) сүзләре белән кулланыла. *Wақыт* сүзе белән кулланылганда алар төп эш-хәрәкәт белән бер вакыт яссылыгында башкарылган процессны белдереп киләләр. Автор *-дық wақыт* конструкциясен башка эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын ачыклаганда файдалана: Господин Шубин арабайа ултырдығы wақытда (اولتردوغى وقتده) қучерена: «Париж»ға илт!» – диде [Бигиев, 1887, б. 13]; Бу тариқа сөйләшеп чәй эчдекләре wақытда (اچدوكلرى وقتده) Муса әфәндейә хадим бер мәктүб килтереп вирде [Бигиев, 1887, б. 18]; Бөйләчә қарт хәзрәтнең Ғабделғафурға улан нәсыйхәтләре тәмам улдығы wақыт (تمام اولديغى وقت) ат-араба дә тәмам вә хәзер улды [Бигиев, 1890, б. 7]; ...Мәмәтнең әйтдеге сүзләренә сақчы солдат күзләрене ачдығы wақытда (آچديغى وقتده) ақчаны алмыш арестант гизлечә ун сумлық кәғәзе кесәсендән чықарып, ағызына қуйып ақрынча чәйнәмәйә башлады [Бигиев, 1890, б. 70].

Әсәрләрдә *-дық сәбәп* конструкциясе башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен күрсәткәндә файдаланыла: ...Хәдичә туташны Муса әфәнде кәләшлеккә алдығы сәбәбендән (آلدوغى سببندن), Ғабденнәсыр әфәндейә Хәдичә туташны вирмәмешләр [Бигиев, 1887, б. 14]; Муса әфәнде мәхбүс улдығы сәбәбдән (محبوس اولدوغى سببدن) һәркәс қайғылы улды [Бигиев, 1887, б. 33]; Бу көнә қәдәр ике ай миқдар ғайәт ағыр хаста улдығым сәбәбдән (خسته اولديغم سببدن), бу қәдәр озақ wақыт сезләрә хат җибәрә алмадым [Бигиев, 1890, б. 17]. Шәһре Нижнийдә мөселманлар мәүҗүд улдығы сәбәбдән (موجود اولديغى سببدن) бу чәйханәдә һәм мөселманлар йуқ дәгел иде [Бигиев, 1890, б. 36] һ.б.

Исем фигыльләр урынында килгән *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр үткәндәге яисә хәзерге заманда дәвамлы рәвештә башкарыла торган, аерым очракларда нинди дә булса заманга карамаган эш-хәрәкәтне атап киләләр. Язучы аларны түбәндәге рәвештә файдалана:

1) баш килештә: ...мәрхүмә ниндәләйен хатын идеге (ايدوكي) дә мәғлүм түгел [Бигиев, 1887, б. 10]; Сез ғазизәләрә мәктүб йазмадығым (يازمادوغم) бәнем тарафымдан олуғ ғайебдер [Бигиев, 1887, б. 68]; Қа-

занда булдыгыңыз (بولنديغڭز) вармы? [Бигиев, 1908, б. 17]; Ләкин 226 сәнәи миладийәдә тәэсис улынмыш дәүләте Сасанийә ибтидаларында бина қылындығы (بنا قيلنديغى) ғөман улыныр [Бигиев, 1908, б. 41];

2) юнәлеш килешендә: Бу табылған мәктүб мөсафирә Зөләйханең мәқтүл булған көнендә йазылдығына (يازولدوغينه) мәктүбдәге числасы дәлилдер! [Бигиев, 1887, б. 8]; Бер ай улды сезне тәрке идеп қачып китдегемә (كيتدوكمه) [Бигиев, 1887, б. 68]; Ләкин, абыстай, баланың тәрбийәсе ичүн шушы ақчаны мәндән алдығыңа (آلديغنكا) бер йазу вир... [Бигиев, 1890, б. 28]; Ләкин сән безне мондый хезмәткә йалладықыңа (ياللاديقنكا) бер кечек кәғәзда улса да бер йазу йазып вир [Бигиев, 1890, б. 53]; Һидайәт бер ходайың әлендә улдығына (ولديغنه) бүйүк бер борһандыр [Бигиев, 1908, б. 36]; Визитә ысулларыны белер бер арқадаш булындығына (بولنديغنه) мәмнүн улдым [Бигиев, 1908, б. 77];

3) төшем килешендә: Әгәр дә ишекне йозақ илә бикләп китсә иде, бу хатынның үлтерелдегене (اولترولدوكنى) белү кәчегеп, қатыйльгә ғизләнергә дә форсат булыр иде [Бигиев, 1887, б. 6]; Муса әфәнденең йығладығыны (يغلادوغنى) күреп, Ниғмәтулла әфәнде дә битәқәт булып йығлыйдыр [Бигиев, 1887, б. 14]; Вә политсәдән пожар атларыны тиз-тиз йигеп (қушып), пожарныйларның йанғына китдекләрене (كتدوكلرنى) ишедеп, Маһруй, ... бөйләчә фикерләр қылмайа башлады [Бигиев, 1890, б. 23]; Следовательнең қарчықдан ғади улан сөальләреңдән вә нә хезмәт илә следовательнең хозурына чақырылдығыны (چاقرولديغنى) әйтдекдән соңра... [Бигиев, 1890, б. 33–34]; Волгин җәнабләре дин қарендәшләремез хақында улмыш шу сүзләрендән хәйа идеп қызардығымы (قيزارديغمى) күрәрәк,... [Бигиев, 1908, б. 18];

4) чыгыш килешендә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен күрсәткәндә: Қазан байлары мабәйнендә мәшһүр вә мәғруф бай Әхмәди Хәмидев Хәдичә исемле қызыны йөз мең сум көмеш ақча илә кийәүгә вирдегендән (كياۋكا ويردوكندن) Муса Салихов Хәдичә туташны кәләшлеккә аладыр иде [Бигиев, 1887, б. 9]; Қызның әткәсе, мине йахшы белмәдегендән (بلمدوكندن), қызны бәңа вирергә разый улмады [Бигиев, 1887, б. 22]; Мәнем вәғдәм исә ул wақытда Петербурғда Зөләйхаға ғайәт дә ғашыйқ улдығымдан (عاشق اولدوغمدن), мәрхүмә Зөләйханы кәләшлеккә алу иде [Бигиев, 1887, б. 23];.

Әсәрләрдә *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең чыгыш килешендә башка эш-хәрәкәтнең вакыт ягыннан башлангыч ноктасын (а) һәм кыек объектын (ә) күрсәтү максатыннан кулланылу очраклары да теркәлде:

а) Җиһангирнең Казандан китдегендән (كتدوكندن) бу көнә кәдәр сәкез ай кичде [Бигиев, 1890, б. 16]; Ғабделғафурның мәдрәсәдән мәрдүд улдығындан (مردود اولديغندن) бу көнә кәдәр бер ай wакыт кичде [Бигиев, 1890, б. 51]; ...дөнйайа чыкдығымдан (چقديغمدن) шу көнә кәдәр әксәр ғомреме Субаш кәрибендә кәчердем [Бигиев, 1908, б. 19];

ә) Төн йарымы кичкәч, политсәнең йакынында улан килисәдә колоколлары тиз-тиз ғәҗәлә ормайа-какмайа башладыкларындан (باشلادوقلرندن) күздән йокысы качмыш Маһруй пожар-йанғын барлығын белде [Бигиев, 1890, б. 23]; Бу картчык шәһәр өстенә чығып йөрмәдеге сәбәбдән, үткән кичдә улан кәтелне вә Маһруйның шимди мәхбүсә улдығындан (محبوسه اولديغندن) һич дә хәбәрдар дәгел иде [Бигиев, 1890, б. 27]; Кабере буш – мәйетсез күмдекләрендән (كومدوكلرندن) кемсә хәбәрдар улмадығы өчен... [Бигиев, 1890, б. 60].

*-дык* кушымчалы сыйфат фигыльләрне урын-вакыт килешендә автор түбәндәге очракларда куллана:

а) башка эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын күрсәткәндә: «Хадимәне бу йирә дәғвәт кылыңыз», – дидекләрендә (ديدوكلرونده), Хадимәне дәғwәт кылып килтерделәр [Бигиев, 1887, б. 5]; Бер сәнә мөкәддәм мән Петербурғға вардыкымда (واردوقمده) «Татарский ресторан» исеме илә мәшһүр вә мөғтәбәр чәйханә вә номерләренең 8 нче номеренә дөшдем [Бигиев, 1887, б. 21]; Кызны һәр күрдегемдә (كوردوكمده) кыз бәңа тәбәссем кылып карыйдыр иде [Бигиев, 1887, б. 22];

ә) аерым очракларда башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын тасвирлаганда: ...чөнки Муса Салиховның катыйле Зөләйха идегендә (ايدوكنده) бер дә шик вә шөбһә йук [Бигиев, 1887, б. 30]; Судебный следователь һәм адвокат бу табылмыш йазу мәктүлә Зөләйханың китабәте улдығында (كتابتى اولدوغنده) шик вә шөбһә кылмыйлар иде [Бигиев, 1887, б. 61].

Автор *-дык* кушымчалы сыйфат фигыльләрне *соңра* (صكره), *өчен/ ичүн* (ايچون / اوچون), кеби (كبى) бәйлекләре белән дә куллана. *Соңра* бәйлеге белән килгәндә *-дык* формасы чыгыш килеше кушымчасын ала һәм җөмләдәге башка эш-хәрәкәттән алда башкарылган процессны белдерә. Әсәрдә әлеге конструкция *-гач* кушымчалы хәл фигыльләрне алыштырып килә һәм башка эш-хәрәкәтнең вакыт ягыннан башлангыч ноктасын тасвирлаганда файдаланыла: Йәнә биш-ун дәкыйка кичдекдән соңра (كچدوكدن صنكره): «Киләләр! Киләләр!» – дигән сүз җәмәғәт телендә тәкрар кылына башлады [Бигиев, 1887, б. 4]; ...әткәсе wафат итдекдән соңра (وفات ايتدوكدن صنكره) тажир-сәүдәгәр улмыш [Бигиев, 1887, б. 8];. Йағкуб-

ның өстенә өч-дүрт тас қайнар су салдығымдан соңра (صالدوغمدن صنکره), «тәмам» идәйем дийү, ағач шайқасы-ләгәнлә ике дәфға идәнгә йығылмыш Йағқубның башына ордым [Бигиев, 1890, б. 26]; Бөйлә дүрт-биш дәқиқа кәчдекдән соңра (کچدوکدن صنکره) Жиһангир қайын әнкәсендән... [Бигиев, 1890, б. 39]; Маһруйны қаберстанда қалдырып кәтдекдән соңра (کتدوکدن صونکره) йарым сәғәт миқдар wақыт кичкәч, Маһруй айнымайа вә уйғанмайа башлады [Бигиев, 1890, б. 58].

Аерым очракларда әлеге максатта *-дық бәғдендә* конструкциясе дә кулланыла: Муса әфәнде чәйне тәмам итдеге бәғдендә (تمام ایتدوکی بعدنده) тәһарәтләнеп, йәстү намазына шөруғ қылып, бер рикәғәт намаз қылдығындан соңра Ниғмәтула әфәнде дә ивгә қайтып килде [Бигиев, 1887, б. 9]; Ибраһим Ғалийевнең китдеге бәғдендә (کتدوکی بعدنده) алты йа йиде яшендә улан Ибраһим әфәнденең уғлы Мостафа Әхмерский вә Йағқубның утырмыш йирләренә килеп, Йағқуб әфәндейә бер конверт-хат вирде [Бигиев, 1887, б. 13].

*-дық өчен/ичүн* конструкциясен автор башка эш-хәрәкәтнең үтәлү сәбәбен күрсәткәндә куллана: Мәқтүлә Зөләйханың қатыйле дә тотылып, қәтелдә мәғйүб улдығы өчен (معیوب اولدوغی اوچون) «окружный суд» қатыйлне ун сәнә «каторжный хезмәткә» хөкем қылды [Бигиев, 1887, б. 67]; Господин Шубин: «Шимди Әхмәди байға телеграм суғарға кирәк», – дийү телеғрам суғарға мәслихәт қылдығы өчен (مصلحت قیلدوغی اوچون) мәҗлес тәмам улғач, Ниғмәтулла әфәнде Әхмәди байға бөйлә телеграм йазды [Бигиев, 1887, б. 74]; Хикәйәмезә Ғабделғафурның мәдхәле улдығы өчен (مدخلی اولدیغیچون) Ғабделғафурның кем вә ниндәләйен адәм улдығыны бәйан идәмез [Бигиев, 1890, б. 2]; Хәмзә байның мәүте бәғдендә улан сәнәләр ғайәт ағыр, тиҗарәт вә кәсебдә хайли зарар вә кеп мал тәләф улдығы өчен (تلف اولدیغیچون) Җиһангирнең дәүләт вә байлығына олуғ ноқсан килде [Бигиев, 1890, б. 12].

*-дық кеби* конструкциясе әсәрләрдә башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен тасвирлаганда кулланыла: Қазан шәһәрендә әксәр рус җәмәғәте мөселманча сөйләшә белдекләре кеби (بلدوکلری کبی), мөселманча йазмақ-уқымақ да беләләр [Бигиев, 1887, б. 31]; Присяжный заседатель Муса әфәндейе қатыйле Зөләйха дийү зан қылулары хата улдығы кеби (خطا اولدوغی کبی), господин Шубинның да Ғабденнәсыр әфәндейе қатыйле Зөләйха дийү зан қылуы хата улды [Бигиев, 1887, б. 72]; Ғабделғафурның бу ғәдәтендән бәғзе толлабә хәбәрдар улдығы (حبردار اولدیغی) кеби, дамелла хәзрәтләре һәм бу хәле ишедмеш иде [Бигиев, 1890, б. 50]; Мәмәт, Ғабделғафур вә Ибраһим смотрительнең

бүлмәсендән сабырлыкла, ғәҗәләсез чығып, Исраил балаларының судан қоры чықдықлары кеби (چيقدوقلری كبی); хәбесханәдән қоры чығып хәлас булдылар [Бигиев, 1890, б. 72]; Шу массаж ысулы Бохара хәммамларында мәғруф улдығы кеби (معروف اولديغی كبی), бохариләрең ханәләрендә дә ғайәт мәқбүл имеш [Бигиев, 1908, б. 63].

Р. Фәхретдин әсәрләрендә *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр атрибутив позициядә, исемләшкән хәлдә һәм исем фигыль мәгънәсендә кулланыла. Атрибутив позициядә автор аларны сыйфатланмышларның үткән заманда башкарылган эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен тасвирлаганда файдалана: Мәгәр дә бу сүзләр, анамдан (алла рәхмәт итсен) ишеткән сүзләрнең соңы имеш; чөнки бән Қазанға килдегем (كيلدكم) елда wафат улмыш иде [Фәхретдин, 1899, б. 6]; Исемене онытдығым (اونتديغم) бер ыстансада (мәнзил) ыстудент пароходдан төшеб қалды [Фәхретдин, 1899, б. 27]; Тәрбийәханә туғрысында сурдығың (صورديغك) шәйләр дәфтәрә қайд улынмышдыр,... [Фәхретдин, 1903, б. 77]; Wафат улдығы (وفات اولديغی) сәғәтендә қартчығына ошбу сүзләре сөйләйә белмешдер [Фәхретдин, 1903, б. 105].

Текстларда *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр *wақыт* (وقت) / *заман* (زمان), *сәбәб* (سبب) һәм *хәл* (حال) сүзләре белән кулланыла. *Wақыт* һәм *заман* сүзләре белән кулланылганда ул төп эш-хәрәкәт белән бер вакыт яссылыгында башкарылган процессны белдерә. Автор *-дығы wақыт/заман* конструкциясен башка эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын тасвирлаганда файдалана: Қазанға китдегем заманда (كيتدكم زمانده) Самар – Уфа тимер йулы йаңа эшләнә башланмыш иде [Фәхретдин, 1899, б. 8]; Қазандан айырылдығым wақытда (آيورلديغم وقتده) қазанлы дустларым илә иткән мәҗлесемездә бер ыстудент вар иде [Фәхретдин, 1899, б. 23]; Соңра ақча суға башладықлары wақытда (صوغا باشلادقلری وقتده) бунынла ақчаларың дәрәҗәләре һәм тәғйин иделмешдер [Фәхретдин, 1903, б. 15]; Үгезләр йигеп, арбаларың көпчәкләрене (тәгәрмәч) сары май илә майлап, сырт өсләрендән йөрүләрене сөйләдеге wақытында (سويلدكی وقتنده), дыңлаучылар, кәнделәренең тимер юл, пароход, телеграмм, телефон заманасында идекләрене оныдып, иске дөнйа кешеләре улырлар иде [Фәхретдин, 1903, б. 20]. Җен кеби көчле вә қуәтле йегетләр илә бер аралық дәва нийәте илә дийә җыйылышып-йырлашып эчдекләре бер wақытда (ايچدكلری بر وقتده) арада низағ чықды... [Фәхретдин, 1903, б. 28].

*-дығы сәбәб* конструкциясе әсәрләрдә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен күрсәткәндә файдаланыла: Йаурупа шәһәрләренә күр-

ше улдықлары сәбәбдән (كورشى اولدقلرى سببندن) «мода» динелгән зарарлы хасталық бунлар арасында күрелергә башламышдыр [Фәхретдин, 1899, б. 4]; Һичбер сүземезгә қатышмадығы сәбәпле (قاتوشماديغنى سببلى) мөселман улып-улмадығыны белмәмеш идем [Фәхретдин, 1899, б. 23]; Айақлары улмадығы сәбәпдән (اولماديغى سببدن) бәләкәй арбаға утырып, ике йақдан ике тайақ йәрдәме илә йөрмәкдә улан бу хатыны күреп, зийадә қызғанды [Фәхретдин, 1903, б. 116] һ.б.

*-дығы хәлдә* конструкциясен автор түбәндәге очракларда файдалана:

1) җөмләдәге башка эш-хәрәкәтнең кире шартын күрсәткәндә: Һич тәқwә улмадығы хәлдә (تقوا اولماديغى حالده) тәқwә күренер, беренче дәрәҗәдә залим улдығы хәлдә (ظالم اولديغى حالده) хиҗаж кеби кәндене мәзлум күстәрә белер иде [Фәхретдин, 1903, б. 15]; Ләкин Ғаббас мелланы қулдан йибәрмәк эстәмәдеге хәлдә (استمادكى حالده) берқәдәр назланмақ вә йалындырмақ фикерендә иде [Фәхретдин, 1903, б. 17]; Мәғлүмдер ки, һич эшләре улмадығы хәлдә (اشلرى اولماديغى حالده) қартчықлар дәүләтләр арасында йөрмәкдә улан илчеләр мәртәбәсендә олуғ эшләр башқарып йөрерләр [Фәхретдин, 1903, б. 42] һ.б.;

2) персонажның портретын биргәндә: Ошбу илле йәшләрендә улан Хикмәт хаҗи қарйәләрдә дәгел, шәһәрләрдә назыйры аз улан байларың бере улдығы хәлдә (اولديغى حالده) чиксез надан, рийалы мөтәкәббер бер зат иде [Фәхретдин, 1903, б. 15]; Беренче сафың тәмам урта бер йирендә башында чуар чалма, өстендә сөт кеби ақ җөббә улдығы хәлдә (اولديغى حالده) бер қарт хәзрәт қызлара қаршы тордығы хәлдә (قارشو طورديغى حالده) күреләдер [Фәхретдин, 1903, б. 89] һ.б.;

3) башка эш-хәрәкәтнең башкарылу рәвешен күрсәткәндә: Ун кемсәдән зийадә улдықлары хәлдә (زياده اولدقلرى حالده) җөмләсе бәңа хитабә идәрәк җөмләсе берйулы сөйләрләр [Фәхретдин, 1903, б. 37]; Ушандақ күңлемез үземездә улмадығы хәлдә (اولماديغى حالده) йазамыз [Фәхретдин, 1903, б. 43]; Хатынларың китаб уқыдып утырдықларыны күрдеге илә йанында ничә йыллардан бирү сақлаб йөртмеш бер доғаны уқыдып, мәғнәсене һич белмәдеге хәлдә (بيلمادكى حالده) дыңлады [Фәхретдин, 1903, б. 69] һ.б.

Аерым очракларда автор *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләрне сыйфатланмышларыннан башка да куллана. Бу очракта алар үзләренә күплек сан, тартым, килеш кушымчаларын алалар. Текстларда исемләшкән *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр түбәндәге килешләрдә теркәлде:

1) баш килештә: Бу әйтдекләрем (آیتدکلرم) җөмләсе сезгә мәгълүмдер [Фәхретдин, 1899, б. 13]; Сезең йәшеңездә wақытымызда безем белдегемез (بیلدکمز) сезең белдегеңез (بیلدککز) қәдәр дәгел иде [Фәхретдин, 1903, б. 51];

2) иялек килешендә: Анларың белдекләренең (بیلدکلرینك) туғры улып да, бәнем белдекләремең (بیلدکلرمك) хата идеге хақында бер дәлил сурмақ wазыйфам дәгелме? [Фәхретдин, 1903, б. 62].

3) төшем килешендә: Бу сәбәбдән франсыз китабында қазанлыларның тиҗарәт бабында улған хәлләренә даир йаздықларыны (یازدقلرنی) сорарға қарар вирдем [Фәхретдин, 1899, б. 58];

4) чыгыш килешендә: Буның илә бәрабәр бәғзе берләренең безнең йаздықларымыздан (یازدقلرمزدن) файда алырға мохтаҗ дәрәҗәдә улдықлары инкяр улынмаз [Фәхретдин, 1899, б. 2]; Қырым, Қытай, Иран, һиндстан, Әфғанстан, Тунис, Мисырда улған төрекләр ошбу дидекләремездән (دیدکلرمزدن) таралмышлардыр [Фәхретдин, 1899, б. 57].

Исем фигыльләр урынында килгән *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр үткәндәге яисә хәзерге заманда дәвамлы рәвештә башкарыла торган, аерым очракларда нинди дә булса заманга карамаган эшхәрәкәтне атап киләләр. Язучы аларны түбәндәге рәвештә файдалана:

1) баш килештә: Безнең ислам җәмгыйәтемез ғыйлем вә мәғрифәт, һөнәр вә сәнғәт хосусларында түбән қалдықы (توبان قالدقی) мәғлүмеңездер [Фәхретдин, 1899, б. 10]; Бу хатын вә қызлар пароходқа нә ичүн килдекләре (کلدکلری) мәғлүм улмады исә дә,... [Фәхретдин, 1899, б. 15]; Әгәр дә диққать иделенеп күрелсә иде, мәзкүрә қызың деләнчелегә үгрәнмәдеге (اوکرنمادکی) вә йәки деләнче улырға эстәмәдеге (استمادکی) аңлашылыныр иде [Фәхретдин, 1903, б. 63]; Шөйлә исә дә, җаны бәрабәрендә улан нә қәдәр ақчасыны бу йула фида итдеге (فدا ایتدکی) инкяр улынмаз [Фәхретдин, 1903, б. 76] һ.б.;

2) иялек килешендә: Ләкин Сәлимә туташ асла күренмәз вә бу күренмәдегенең (کورنمدیکینكٔ) сәбәбене һәм белмәз идем [Фәхретдин, 1899, б. 75]; Хәзрәт баласыны имамлықға алмадықымызың (آلمادقمزك) сәбәбе ошбудыр, бай! [Фәхретдин, 1903, б. 85] һ.б.;

3) юнәлеш килешендә: Исламийәтнең мәсләге ғали идегенә (عالی ایدکینه) қамил қәнәғәт итдем [Фәхретдин, 1899, б. 25]; ...үз қаwем вә қабиләмез хақында франсыз әсәрендән бер Иран қызы васыйтасы илә бу қәдәр сүз ишетдегемә (ایشتدکمه) һәм тәғәҗҗеб, һәм тәәссеф итдем [Фәхретдин, 1899, б. 57]; Wақыйған бу мелла илә Ғаббас мелла арасында мөхарәбә юлы ачылдығына (آچلدیغنه) Хикмәт бай шадланды

исә дә,... [Фәхретдин, 1903, б. 30]; Мәҗлесеңезең бөйлә низамсыз улдығына (نظامسز اولديغنه) тәәсеф итдем [Фәхретдин, 1903, б. 37] һ.б.;

4) төшем килешендә: Йиде-сигез ғасырлар мөқәддәм хәтта ки ғарәб халықлары кәмәләр илә сәүдә йөртдекләрене (سودا يورتدكلرنى) вә андан мөқәддәм нә қәдәр суғышлар улып, халықлар бер-берене ошбу йылға өстендә таладықларыны (تالادقلرنى) хәтерләб, хәзерге замананың тынычлығы ичүн шатланыр идем [Фәхретдин, 1899, б. 22]; Бән һәм үземнең кем идегемне (كم ايدكمنى), сүзләр қәдәр фарсыча белмәдегемне (بيلمدكمنى), ләкин аңладықымны (آڭلادقمنى) бәйән итдем [Фәхретдин, 1899, б. 32]; Мәсәлән, Сәлим бабайның тәмәке тартдығыны (تماكى تارتديغنى) йәшереп қалдырмыйурмыз [Фәхретдин, 1903, б. 23]; Ғаббас мелла исә Мусаның исемене ишетмеш исә дә, шәхесене танымадығыны (تانيماديغنى), хат вә дәфтәр вирмәк дәгел, бәлки бу кеби эшдән асла хәбәрдар дәгел идегене (خبردار دگل ايدكنى) сөйләде [Фәхретдин, 1903, б. 34] һ.б.;

5) чыгыш килешендә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен (а) һәм кыек объектын (ә) күрсәткәндә:

а) Русча белмәдегендән (بيلمدكندن) хатны тотып, хадим илә та урыныма қәдәр килмеш вә ишарәт илә бәңа тапшырылырға тиеш идегене белдереп, үзе кире дүнмеш имеш [Фәхретдин, 1899, б. 30]; Бу олуғ сәүдәгәрнең Сәлимә туташ илә ошбу хатындан башқа варисы улмадығындан (اولماديغندن) Сәлимә туташның Мисырдан қайтуы лязем күрелмеш [Фәхретдин, 1899, б. 34]; Ғайшә абыстай әгәр дә дәүләтле кемсә қызы улса иде, Ғаббас меллаға дәгел, бәлки аның хәлфәләренә йар улачақ иде, ләкин дәүләтсез улдығындан (دولتسز اولديغندن) мәзкүргә йар улды [Фәхретдин, 1903, б. 11]; Ләкин чуқ шөкер улсын ки, Йосыф бабайның йәш wақытында ғайрәте Камал вә қайыш-қамчысы да күз алдында тордығындан (طورديغندن), аз-аз йулға кереп, балалары улдығы соңында тамам бер йахшы қартчық исемене алмыш иде [Фәхретдин, 1903, б. 47] һ.б.;

ә) ... безнең қаwемемездән вә ислам динендә идекләрендән (اسلام دينده ايدكلرندن) хәбәрләре йуқдыр [Фәхретдин, 1899, б. 27]; ...дөнйада бөйлә сүзләр вә бөйлә тәғбирләр вар идегендән (وار ايدكندن) дә хәбәрдар дәгелләр иде [Фәхретдин, 1899, б. 54]; Зирә бер-беренең wафат улдықларындан (وفات اولدقلرندن) һич шөбһәләре улмадығындан башқа, қыйәфәтләрендә улан үзгәрмәк, бөйлә ихтимала юл вирмийур иде [Фәхретдин, 1903, б. 128];

6) урын-вакыт килешендә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын күрсәткәндә: Хатынлары қалпақ, тақыйа, читек, кәвеш кийеп,

урамға чыкдықларында (چقدقلرنده) чапан бөркәнәләр [Фәхретдин, 1899, б. 3]; Бүлмәгә кердегемдә (كردكمده) Сәлимә тирләп-пешеп нәрсәләрене урнашдыра иде [Фәхретдин, 1899, б. 18]; Иске тарихларымызы сөйләдегендә (سويلدكنده) иске ғасырларны вә иске ғасырның халықларыны тәмам күз уңына китерер иде [Фәхретдин, 1903, б. 20]; Киленләрене сүгеп, қырып, бимаза идеп йөрмәкдә улан қайнаналар буның қурай вә яки йырладығы давышларыны ишетдекләрендә (ایشتدكلرنده) май кеби йомшарып кидәрләр,... [Фәхретдин, 1903, б. 22] һ.б.

Автор *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләрне *соң* (سوڭ), *өчен/ичүн* (اوچون / ایچون), *кеби* (كبی), *илә* (ایله), *қәдәр* (قدر), *күрә* (كوره) бәйлекләре белән дә куллана.

*Соң* бәйлеге белән килгәндә *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр чыгыш килешендә кулланылалар. Әлеге конструкция җөмләдәге башка эш-хәрәкәттән алда башкарылган процессны белдерә. Автор аңа икенче эш-хәрәкәтнең вакыт ягыннан башлангыч ноктасын күрсәткәндә мөрәҗәгать итә: Бер урын булып әшйаларымны қуйдықым соңында (قويدقم سوڭنده) бәғьзе хажәтем ичүн дәхи вардым [Фәхретдин, 1899, б. 18]; Тәрбийәле қызлар хатын улдықлары соңында (خاتون اولدقلری سوڭنده) бер өйне ғақыл илә идарә қылырлар,... [Фәхретдин, 1899, б. 68]; Ғаббас мелланың сәфәрендән ике вә Йанбәг шәһәрендән йазмыш улан соң хатындан бер ай үтдеге соңында (اوتدكی صوكنده), Ғайшә абыстай қулына чит мәмләкәт (Төркия дәүләте) марқасы илә бер мәктүб вирелде [Фәхретдин, 1903, б. 40]; Өч һафта миқдары салынмыш урынында ятдығындан сон (یاتدیغندن صوك), қултық таяғына таянып хастаханә эчендә йөрмәйә рөхсәт улынды [Фәхретдин, 1903, б. 68] һ.б.

*-дық өчен/ичүн* конструкциясен автор башка эш-хәрәкәтнең үтәлү сәбәбен күрсәткәндә куллана: ...бунларның бере ислам ғыйлемләрендән хәбәрсез вә икенчесе әхwәле дөнйадан мәғлүматсыз қалдықлары ичүн (معلوماتسز قالدقلری ایچون), халқымызға йул башчысы ула алмазлар [Фәхретдин, 1899, б. 10]; Һәм дә күбесе иң бозық вә фәна ғәдәтләрне гүзәл идеп күстәрдеге ичүн (كوستردیكی ایچون) һич ғафу иделмәздер җә дә ғайебле улыр [Фәхретдин, 1899, б. 25]; Ничә йыллар Қазанда торып, иске Болғарны бер мәртәбә улсын килеп күрмәдегем ичүн (كورمادكم ایچون) тәәссеф итдем [Фәхретдин, 1899, б. 28]; Бунлар үзләренең балаларыны бөйлә бер тырышлық илә тәрбийә итдекләре ичүн (تربیه ایتدكلری ایچون), бөйлә олуғ өмидләр итмәкдә хақсыз дәгелләр иде [Фәхретдин, 1903, б. 15] һ.б.

*-дық кеби* конструкциясе әсәрләрдә түбәндәге очракларда кулланыла:

а) башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен тасвирлаганда: Бу бабаларымыз мал табарға белдекләре кеби (بيلدكلرى كبى) сарф идәчәк урынларны гүзәл белерләр иде [Фәхретдин, 1899, б. 11]; Динләрнең һич берсе усаллық илә бойырмадығы кеби (بيورماديغى كبى), ислам дине дә тәхсин әхлақ илә тәклиф идәдер [Фәхретдин, 1899, б. 25]; Мәғлүм заманы йитешмәздән мөқәддәм йөк тартдырылмыш ат имгәнеп, эшдән чықтығы кеби (اشدن چقديغى كبى), wақыты җитмәздән мөқәддәм сабақ уқытдырылмыш бала һәм имгәнеп қалмақдадыр [Фәхретдин, 1903, б. 12]; Кәндесе ғөмер барынча хосусан исламлар файдасына бер тийен улсын ақча сарыф итмәдеге кеби (صرف ايتمادكى كبى), бер сәтер улсын йазу вә һәм йазмамыш иде [Фәхретдин, 1903, б. 52] һ.б.;

ә) затка хас булган нинди дә булса сыйфатның дәрәҗәсе, аның рухи халәте турында йазганда: Хәлбуки бу ике сыйфат Мусада қамил улдығы кеби (كامل اولديغى كبى), бунының өстенә зийадә мәкерле, ялғанчы, бозық күңелле, этдән зийадә тамағлы, ифтира вә бөһтан идүче вә һич сақланмай ғайбәт сөйләүче иде [Фәхретдин, 1903, б. 33].

*-дық илә* конструкциясен автор башка эш-хәрәкәтне башкарылу вакытын күрсәткәндә файдалана: Мәгәр дә конторга вардығым илә (وارديغم ايله) бер ғруһ халық бәне қаршы алып, озадырға килдекләрене вә бәнем ичүн билет алып урын хәзерләдекләрене бәйан итделәр [Фәхретдин, 1899, б. 9]; Бәне күрдеге илә (كوردكى ايله) шәлене алып башыны үртде һәм туғры қараб, пароход илә нә қәдәр варачақымны сурды [Фәхретдин, 1899, б. 18]; Бундан башқа хастаханәдә бер мөслимә хадимә улып, бу йәш қызың йазу уқымайа белдегене аңладығы илә (آڭلاديغى ايله) буш wақытларында төркичә китаблар китереп, бундан уқыдыр вә кәндесе ғайәт ихлас үзәрендә динләб торыр иде [Фәхретдин, 1903, б. 68–69]; Йәш хатын алан қартлар бераз дивана улырлар, бу қабилдән хаҗи дә бәне алдығы илә (آلديغى ايله) йарым дивана улмыш иде [Фәхретдин, 1903, б. 71] һ.б.

*-дық қәдәр* конструкциясен автор затка хас булган нинди дә булса сыйфатның дәрәҗәсен, аның рухи халәтен тасвирлаганда куллана: Қашки аңладығым қәдәр (آڭلاديغم قدر) фарсычаны сүзләргә вә жаwаб вирергә белсәм иде,... [Фәхретдин, 1899, б. 17]; Хәлбуки җаным эстәдеге қәдәр (استه دكى قدر) йөрәгем қурқыр иде [Фәхретдин, 1899, б. 18–19]; Сәлимә туташ әдәбле улдығы қәдәр (ادبلى اولديغى قدر) мәхбүб, ғыйлемле улдығы қәдәр (علملى اولديغى قدر) ләтыйф иде [Фәхретдин, 1899, б. 32] һ.б.

*Күрә* бәйлеге белән *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр юнәлеш килешендә кулланылалар. *-дығына күрә* конструкциясе текстларда

кереш җөмләләр составында очрый: Зира ғақыл әхелләре вә әхлақ ғоләмәсенең иттифақ итдекләренә күрә (اتفاق ايتدكلرينه كوره), «сәфахәтдә рәхәт йуқдыр», бәлки асыл рәхәт ғаилә эчендә вә ғаиләләре идарә идүче ибдәшләр йанындадыр [Фәхретдин, 1903, б. 14]. Шөйлә ки, йуқарыда һәм аңлашылдығына күрә (آڭلاشلديغنه كوره), бу қарйа халқы кәсеб ичүн әтрафа вә йырақ йирләрә таралмақда имеш [Фәхретдин, 1903, б. 87].

Аерым очракларда әлеге конструкцияне автор башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен күрсәткәндә файдалана: Бикбулат хәзрәт сәғәдәтене қаршыда кийенеп, бизәнеп тормақда улан хатындан ғибәрәт дийә белдегенә күрә (بيلدكنه كوره) әүwәлге хатыныны балалары илә ағладып чықарып йибәрмеш иде [Фәхретдин, 1903, б. 108].

Ф. Кәрими әсәрләрендә *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр атрибутив позициядә һәм исем фигыль мәгънәсендә кулланылалар. Атрибутив позициядә автор аларны сыйфатланмышларның үткән заманда башкарылган эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесен тасвирлаганда файдалана: ...вә Москва бәләдиясенең дәхи сәнәви варидаты (доходы) ун миллион рублә қарарында идеге бақдығымыз (باقديغمز) рәхбәрдә йазылмыш иде [Кәрими, 1902, б. 17–18]; Без вардығымыз (وارديغمز) ақшам Русия мәшһүр шағирләрендән «Евгений Онеғин» нам әсәре тасвир иделде [Кәрими, 1902, б. 37]; Без чәйемезе тәмам идеп Самарадан алдығымыз (آلديغمز) газеталары уқымаға әлемезә алмыш идек, мәзкүр ике татарың бере йанымыза килеп сәлам вирде [Кәрими, 1908, б. 12]; Йаурупалыларың кичердекләре (كچديكلرى) бу хәлләр, шимди безем башымыздадыр [Кәрими, 1908, б. 20] һ.б.

Текстларда *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр еш қына *wақыт* (وقت) / һәм аерым очракларда *сәбәбле* (سببلى) сүзләре белән кулланыла.

*Wақыт* сүзе белән бергә килгәндә ул башка эш-хәрәкәт белән бер вакыт яссылыгында башкарылган процессны белдерә. Автор *-дық wақыт/заман* конструкциясен башка эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын күрсәткәндә файдалана: Гәрчә бән мәктәбдә уқыдығым wақыт (او قوديغم وقت) берқәдәр машина фәне күрмеш исәм дә,... [Кәрими, 1902, б. 20]; Вә мосахәбәт идеп утырдығымыз wақыт (مصاحبت ايدوب اوطورديغمز وقت) йанымыза бер қарт адәм килеп кирәрәк... [Кәрими, 1902, б. 38]; Без вардығымыз wақыт (وارديغمز وقت) Исмәғыйль бәк кәнде ханәсендә йуқ иде исә дә,... [Кәрими, 1908, б. 62] һ.б.

*-дық сәбәбле* конструкциясе язучы тарафыннан башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен күрсәткәндә кулланыла: ...зиһене вә фике-

ре чуалдыгы сәбәбле (چوبالديعى سببلى), табиғәт тарафындан вирелмеш ғақлыны да ғаиб идеп, бер адәм янына варып өч-биш кәлимә сүз сөйли алмазлық дәрәҗәдә ашағы қалмышдыр [Кәрими, 1908, б. 13–14]; Иран вә Һиндстан кеби тәғәссеб диненең қуәтле мәркәзләрендә мөселман хатынларының ачық гиздекләре сәбәбле (كزديكلرى سببلى), бәғзән бүйүк бәлаләр вә хәтта үлемләр билә wақыйғ улыйур [Кәрими, 1908, б. 54].

Исем фигыльләр урынында килгән *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр үткәндәге яисә хәзерге заманда дәвамлы рәвештә башкарыла торган, аерым очракларда нинди дә булса заманга карамаган эш-хәрәкәтне атап киләләр. Язучы аларны түбәндәге рәвештә файдалана:

1) баш килештә: Петербурғда бу қәдәр биңләрҗә мөселман мәүҗүд улып һәркәс ичүн қатғыйан фарыз улан дин, иман, ғәмәл вә ғыйбадәт илә ана делемезе үгрәдәчәк бер мәктәбе ибтидаи билә булынмадығы (بولنمديغى) шаян тәғаҗҗебдер [Кәрими, 1902, б. 39–49]; Бунларың беренҗесе ичүн йегерме биш миллион рублә масраф чықдығы (مصرف چيقديغى) риwайәт улынмақдадыр [Кәрими, 1902, б. 53]; Мәғәрифле барышня илә гүзәл-гүзәл мосахәбәтләр идеп вардығымыздан wақытын кәчдеге (كچديكى) тойылмадан да қалмыш [Кәрими, 1908, б. 21]; Безә йақын улдықларындан сүзләре вә хәтта нә сөйләшдекләре (سويلشدكلرى) аерым ачық ишеделеп торыйурды [Кәрими, 1908, б. 109] һ.б.;

2) иялек килешендә: Москвайа килдегемезең (كلديكمزڭ) өченҗе көне Шакир әфәнденең эшләре арқасындан гиздек [Кәрими, 1902, б. 19]; ...урайа кидеп тәхсил итдегемең (تحصيل ايتديكمك) сәбәбене кәндем дә лайықы илә билмийурым [Кәрими, 1902, б. 93]; Бурада китап, газета кеби шәйләре бу қәдәр диққать илә бақдықларының (باقدقلرينڭ) сәбәбе шудыр ки,... [Кәрими, 1902, б. 168] һ.б.;

3) юнәлеш килешендә: Сандықларымызы, чанталарымызы ачдырмады, гүмрүкдә бақылдығына (باقلديغنه) ишарәт улмақ үзәрә үзрәләренә кечек-кечек маркалар йапышдырды [Кәрими, 1902, б. 61]; Туғры кәнде йанына инмәдегемезә (اينمديكمزه) тәәссефләр итде [Кәрими, 1902, б. 103]; Низам, интизам вә фәғилийәт күрелән йирләрдә инсаның рухы қуәтләнийур, хәйәте артыйур, қальбе иғтила идийур вә дөнйайа килдегенә (دنيايه كلديكنه) сәвинийүр [Кәрими, 1908, б. 21] һ.б.;

4) төшем килешендә: Насылса да бер йирдән сүз ачып кәндесенең докторлара инанмадығыны (اينانماديغنى) вә бу замандағы табибларың бер шәй дә белмәдекләрене (بيلمديكلرينى) вә иске замандағы чин докторларының пәк маһир улдықларыны (ماحر اولدقلرينى) ... татлы бер сурәтдә

бәйан итде [Кәрими, 1902, б. 29]; Хәтта лисанлары беленмәсә дә, уйнадыкларыны (اوينادقلرينى) аңламак мөмкиндер [Кәрими, 1902, б. 37]; Барышня безем кем улып, нәрәйә китдегемезе (كيتديكمزى) вә без аның нәрәле улдыгыны (نره لى اولديغنى) вә безем илә бәрабәр чук мөддәтме варажагыны сурдык, танышдык, сүз ачылды [Кәрими, 1908, б. 16]; Әвәт, әфәндем, ханлар инсаның бу дөнйайа ялгыз бер дәфа килдегене (كلديكنى) пәк ийи белмешләрдер [Кәрими, 1908, б. 66] һ.б.;

5) чыгыш килешендә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу сәбәбен күрсәткәндә:: ...бу кысымдагы шәйләр Шакир әфәнденең зийадәсе илә назары диккатене җәлеб итдегендән (جلب ايتديكندن) бәгзе машиналары тәхлил вә тәркиб итдереп вә бәгзесыны хәрәкәтә китереп бакды [Кәрими, 1902, б. 28]; Бу ике арада поездлар чук хәрәкәт итдегендән (حركت ايتدكندن) вагонларда Русиянең башка җәһәтләрендәге дәрәҗәдә галәбәлек улмыйур [Кәрими, 1902, б. 31]; ...кәнделәре Аурупа делләрене белмәдекләрендән (بيلمديكلرندن) вә тиҗарәт гыйлемләрендән бихәбәр улдыкларындан (بى خبر اولدقلرندن), табигый, симез тарафы нимсәләр илә йәһүдиләр кесәсенә акмакдадыр [Кәрими, 1908, б. 7]; ...берничә дәфгалар көллийәтле сурәтдә Төркийәйә һиҗрәт итдекләрендән (هجرت ايتديكلريندن), әүwәлгейә нәзаран шимдики хәлдә чук азалмышлардыр [Кәрими, 1908, б. 33] һ.б.

6) урын-вакыт килешендә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын тасвирлаганда: Вә бөйлә сурдыгымы тәгаҗҗеб итмәйеңез, безем остазымыз бер адәм илә күрешдекдә (كوريشدكده) бөйлә сурыйур иде, диде [Кәрими, 1902, б. 40]; Бурайа йакынлашдыгымызда (ياقلاشديغمزده) жандармлар паспортларымызы туплайып алдылар [Кәрими, 1902, б. 60]; Сәгәт йиде карарларында Ряжскидан кузгалып китдегендә (قوزغالوب كيتدكده), барышня илә үтә-бирүдән сүзләр ачыларак, гәнә мосәхәбәтә дәвам итдек [Кәрими, 1908, б. 21]; Пайтәхетдә торужы вә мәдәнийәт галәмендә йәшәүҗе мөселманлардан бу кадар сафсата вә мәгнәсез сүз ишеттекдә (ايشتدكده) йөрәгем туңып калды,... [Кәрими, 1908, б. 28] һ.б.

Автор *-дык* кушымчалы сыйфат фигыльләрне *соңра* (صڭره), *өчен/ичүн* (ايچون / اوچون), *кеби* (كبى), *күрә* (كوره) бәйлекләре белән дә куллана.

*Соңра* бәйлеге белән килгәндә *-дык* формасы чыгыш килеше кушымчасын ала һәм җөмләдәге башка эш-хәрәкәттән алда башкарылган процессны белдерә. Әсәрләрдә әлеге конструкция *-гач* кушымчалы хәл фигыльләрне алыштырып килә һәм башка эш-хәрәкәтнең вакыт ягыннан башлангыч ноктасын күрсәткәндә файдаланыла: Хәзрәтдән

чыкып җомға намазы қылдықдан соңра (نمازى قيلدقدنصكره) мөсафирханәмезә ғәудәт идеп қарын туйдырдық... [Кәрими, 1902, б. 31]; Бундан чыкдықдан соңра (چيقدقدنصڭره) Петербургың моғтәбәр мөселманларындан улан Ғалим Морза Мақсудовы зийәрәт итдек [Кәрими, 1902, б. 40]; Самарадан қузғалып китдекдән соңра (قوزغالوب كيتدكدنصڭره) чәй эчмәгә башладық [Кәрими, 1908, б. 12]; Харьковы кәчдекдән соңра (كچدكدنصڭره) hawалар гүзәлләнеп, Русийәнең җәнүб тарафларының ләтафәте мөшаһадә улынмаға башлады [Кәрими, 1908, б. 30] h.б.

*-дық өчен/ичүн* конструкциясен автор башка эш-хәрәкәтнең үтәлү сәбәбе турында язганда куллана: Бинаән ғаләйһи, кәнде милләтләренең бу җәһәтләрдә пәк киредә улдықларыны күрдекләре ичүн (كوردكلرى ايچون) зийадәсе илә тәәссеф идийурлар... [Кәрими, 1902, б. 24]; Бәлки мөселманлар кәнде балаларыны шунлара йулладықлары ичүн (يوللادقلرى ايچون) бу җәһәте әһәмийәтсез қалмышдыр [Кәрими, 1902, б. 38]; Әүwәлге поезддан инеп қалдығымыз ичүн (اينوب قالديغمز ايچون) чуқ мәмнүн улдық [Кәрими, 1902, б. 166] h.б.

*-дық кеби* конструкциясен автор түбәндәге очракларда файдалана:

1) башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен тасвирлаганда: Җаһил рөэсаи руханийә кәнде фикер қасыйранәләре илә дине үзләре эстәдекләре кеби (ایستدیكلرى كبى) тәсарыф идәрәк, файда йиренә бер чуқ зарар вирийурлар [Кәрими, 1908, б. 18]; ...чалышқан вә ғайрәтле Қазан татарлары сәүдә вә тиҗарәт, йахуд саир дөрле хезмәтләр илә ... бөтен Себерә, Манчжурияйә, Төркестана вә Чин эчәреләренә вардықлары кеби (واردقلرى كبى) Қырым вә Кавказ қыйтғаларыны да үзләренең вөҗүдләрендән мәхрүм итмәмәкдәдерләр [Кәрими, 1908, б. 37]; Қоры тарафындан вәхши татарлар һөҗүм итдеге кеби (هجوم ايتديكى كبى) гәнә шул заманда диңгез тарафындан килеп румлара мәдәнийәтле икенҗе бер халық – Җәнәвиздән килмеш итальянлар һөҗүм итмәгә башламышлар [Кәрими, 1908, б. 40];

2) башка эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын күрсәткәндә: Берлина васыл улып вокзала иңдегемез кеби (ايندیكمز كبى) әшйамызы хаммала йөкләтәрәк қапыйа килмәк ичүн франсызҗа сөйләйеп бақдым исә дә, зәхмәтем буша чықды [Кәрими, 1902, б. 63–64]; ...калош вә қалын пальто-фәлән илә гизән һичбер адәм улмадығыны вокзалдан чықдығымыз кеби (چيقديغمز كبى) мөшаһадә итмеш идек [Кәрими, 1902, б. 67]; Кәндесенең исемене ишетдегем кеби (ايشتديكم كبى) бу затың кем вә нәрәле улдығы вә нә wақыт танышдығымыз хәтеремә килде [Кәрими, 1908, б. 56]; Сарайы күрмәк эстәйән адәмләр кәндесенә хәбәр

вирдекләре кеби (خبر ويرديكلرى كبى) сарайларың қапыларыны ачып кәндесе күрсәтеп, һәрбер йире хақында мәғлүмат вә изахат вирийур [Кәрими, 1908, б. 64] һ.б.;

3) чагыштыруларда: Бу тиатро бинасының дышары тарафындан күренеше пәк ғәзәмәтле улдығы кеби (عظمتلى اولديغى كبى), эчәресендәге зиннәт вә интизамы дәхи пәк мөкәммәл иде [Кәрими, 1902, б. 18]; Ғомум мәмалике шәрқыйәдә улдығы кеби (اولديغى كبى) Қырымың дәхи һәр йирендә бер ләтафәт вә һәр йирендә бер шиғрийәт вардыр [Кәрими, 1908, б. 46].

*-дық күрә* конструкциясе текстларда кереш җөмләләр составында кулланыла: Бәйәннамәдә йазылдығына күрә (يازلديغنه كوره), Централь отелең алты йөздән зийадә хадиме вардыр [Кәрими, 1902, б. 66]; Тәмам вокзалың йанында улан бу килисәнең әсасы унберенҗе ғасырда қорылмыш улып, биң сәнә қәдәр бина иделмеш вә, рәһнамәдә әйделдегенә күрә (رهنماده ايدلديگنه كوره), бәғзе йирләре халә тамам улмамышдыр [Кәрими, 1902, б. 90]; ...анлардан аңладығыма күрә (آڭلاديغمه كوره), шәриғәте исламийәнең хатынлар хақындағы әхкәме ғайәт ғадәләт вә хөррийәт үзәрәдер [Кәрими, 1908, б. 22].

Иске татар әдәби теленең традицион үзенчәлекләреннән саналган һәм госманлы төрек теле өчен хас булган *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең барысы өчен дә хас. Чыганакларда алар нигездә атрибутив позициядә һәм исем фигыль функциясендә киләләр һәм хәзерге татар әдәби телендәге *-ган* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләрнең грамматик синонимнары буларак файдаланылалар.

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр шигъри әсәрләрдә, газета текстларында һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә кулланылалар [Юсупов, 2006, с. 111–113; Миннуллин, 2012, с. 197–198; Абдулхаков, 2007, с. 20]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар, ярым чәчмә һәм ярым тезмә формада иҗат ителгән дастаннардан кала, бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норма, норма вариантлылыгының бер күрсәткече булып торалар.

*Хәл фигыль.* Башка затланышсыз фигыль формаларыннан аермалы буларак, хәл фигыль сөйләмдә төп процессны ачыклап килгән икенче бер өстәмә эш-хәрәкәтне белдерә. Заман мәгънәсен үзенчәлекле рәвештә белдерү сәбәпле, хәл фигыль формалары сыйфат

фигыльләр кебек заман мәгънәсен белдерү буенча төркемләнмиләр. Алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең үтәлү вакыты сөйләү моментына түгел, ә бәлки җөмләдәге төп фигыльнең заманына мөнәсәбәттә ачыклана.

Хәзерге татар әдәби телендә хәл фигыльләрнең кулланылыш даирәсе, мәгънәләре һәм функцияләре шактый киң. Аларның төп функциясе – җөмләдә башка фигыль белән белдерелгән эш-хәрәкәтне үтәлү рәвеше, вакыты, сәбәбе һәм максаты ягыннан ачыклау. Моннан тыш, кайбер хәл фигыльләр затланышлы фигыль формалары белән бергә җөмләдәге төп-эш хәрәкәтнең үтәлү дәрәҗәсен белдерә торган аналитик төзелмәләрдә дә кулланылалар.

Татар теле диалектларда хәл фигыльнең унөч формасы теркәлгән [Юсупов, 2004, с. 122–186]. Хәзерге татар әдәби телендә аның биш формасы норма буларак аерып чыгарыла: *-п, -а, -гач, -ганчы, -ышлый* [Татар грамматикасы, 2002, б. 290–298; Тумашева, 1978, б. 147–158; Хисамова, 2006, б. 256–263].

Хәзерге татар әдәби телендә норма буларак кабул ителгән кайбер хәл фигыльләрнең XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы иске татар әдәби телендә дә актив хәрәкәттә булганлыгы күзәтелә. Шуның белән бергә бу чорга караган язма текстларның тел тукымасын гомумтөрки, татар һәм угыз, аерым алганда госманлы төрек телләре өчен хас булган хәл фигыльләре дә тәшкил итә. Язма текстлардан күренгәнчә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби телендә хәл фигыльнең парадигматик һәм синтагматик мәгънәләре *-ып, -а, -гач, -арак, -ынча, -дықча, -маздан, -кән* кушымчалы формалар белән белдерелә.

*-ып* кушымчалы хәл фигыльләр. Классик иске татар язма әдәби теленең традицион үзенчәлекләреннән саналган *-ып* кушымчалы хәл фигыльләр – XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләре текстларында иң еш кулланылган формаларның берсе. Алар фигыль нигезенә *-ып/-еп, -п* (وب-, ب-) кушымчасы ялганып ясалалар: йөгереп (يوكروب) [Акъегет, 1886, б. 4], туқып (توقوب) [Акъегет, 1886, б. 10], тәғаҗҗебләнеп (تعجبلنوب) [Бигиев, 1887, б. 10], тәбәссем қылып (تبسم قيلوب) [Бигиев, 1887, б. 22], сабырсызланып (صبرسزلنوب) [Бигиев, 1887, б. 38], сорап (صوراب) [Бигиев, 1887, б. 54], сөйләшеп (سويله شوب) [Бигиев, 1890, б. 9], қычқырып (قچقروب) [Бигиев, 1890, б. 17], эзләп (ازلب) [Бигиев, 1890, б. 55], башланып (باشلانوب) [Фәхретдин, 1899, б. 2], уздырып (اوزدروب) [Фәхретдин, 1899, б. 6], түгеп (توگوب) [Фәхретдин, 1899, б. 7], фикер идеп (فكر ايدوب) [Фәхретдин, 1899, б. 10], өмид

идеп (امید ایدوب) [Фәхретдин, 1903, б. 8], тикшереп (تیکشروب) [Фәхретдин, 1903, б. 11], батырып (باطوروب) [Фәхретдин, 1903, б. 26] һ.б.

Аерым очракларда нигезе сузыкка тәмамланган фигыльләрдә, төрек телендәге кебек, хәл фигыль кушымчасы алдыннан интервокаль [й] тартыгы өстәлергә мөмкин: узайып (اوزایوب) [Акъегет, 1886, б. 2], уғрайып (اوغریوب) [Бигиев, 1890, б. 11], җылмайып (جلمایوب) [Фәхретдин, 1899, б. 38], моңайып (موڭایوب) [Фәхретдин, 1903, б. 20], тарайып (تارایوب) [Фәхретдин, 1903, б. 28].

Бу үзенчәлек аның юклык формасында да күзәтелә: забт идәмәйеп (ضبط ایده میوب) [Акъегет, 1886, б. 6], хәбәрдәр улмайып (خبردار اولمیوب) [Акъегет, 1886, б. 11], белмәйеп (بلمیوب) [Акъегет, 1886, б. 15], чыдамайып (چدامیوب) [Акъегет, 1886, б. 16], аңламайып (آنلامیوب) [Бигиев, 1890, б. 12], тәкәте қалмайып (طاقتی قالمیوب) [Бигиев, 1890, б. 34], қолақ вирмәйеп (قلاق ویرمیوب) [Бигиев, 1890, б. 48], айрылмайып (آیرلمایوب) [Фәхретдин, 1903, б. 42], белмәйеп (بیلمیوب) [Фәхретдин, 1903, б. 115].

Сөйләмдә *-ып* кушымчалы хәл фигыльләр төп эш-хәрәкәт белән вакыт мөнәсәбәтенә кереп, аның белән бер үк вакытта, яисә аннан алда башкарылган эш-хәрәкәтне белдереп киләләр. Татар тел белемендә бу аларның төп мәгънәсе буларак билгеләнә. Моннан тыш, төп фигыль белән төрле вакыт мөнәсәбәтләренә кергән *-ып* кушымчалы хәл фигыльләр аның үтәлү рәвешен, сәбәбен, максатын, ә аерым очракларда кире шарт мәгънәсен дә белдерәләр [Татар грамматикасы, 2002, 293–295; Тумашева, 1978, б. 151–152; Хисамова, 2006, б. 258–260]. Әлеге мәгънәләрдә алар XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә дә теркәлде.

Төп фигыль белән бер үк вакыттагы эш-хәрәкәтне белдергән *-ып* кушымчалы хәл фигыльләр язучылар тарафыннан күпчелек очракта төп эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен тасвирлаганда кулланылалар: Кәндесене забт идеп (ضبط ایدوب), уқымайа гәнә чалышыр [Акъегет, 1886, б. 6]; Анчақ йақында кечек бер су черелдәп (چرولداب) ақыйур [Акъегет, 1886, б. 37]; Муса әфәнде Ниғмәтулла абзасы илә бергә сәүдә қылып (سوده قیلوب), бер әвдә торадыр иде [Бигиев, 1887, б. 9]; Муса әфәнде бер нәрсә дә җаwаб вирмәйенчә тәфәккердә тәғәҗҗебләнеп (تعجبلنوب) ултырадыр [Бигиев, 1887, б. 10]; ...Ибраһим Ғалийев, қарчық-акушеркайы алдалаб, баланың қәтеленә ғайрәт қылып (غیرت قیلوب), баланы «тәмам» қылдырды [Бигиев, 1890, б. 33]; Маһруйның әнкәсе, бу сөалә җаwаб вирмәйенчә, кечек балалардан зийадәрәк тавыш илә қычқырып (قچقروب) җығламайа башлады [Бигиев, 1890, б. 38]; Буңа қаршы

уларақ бән дә Хуҗа Насретдин ләтыйфәләрене хикәйәт вә тәрҗемә идеп (ترجمه ایدوب), туташны көлдерер идем [Фәхретдин, 1899, б. 51]; Қуық мисалында қабарып, мәдрәсәдән мәдрәсәгә мөназарә идешеп йөрдекләремне хәтерләп, тирләргә батып (تیرلرگا باتوب) ойаладыр идем [Фәхретдин, 1899, б. 54] һ.б.

Язма чыганакларда *-ып* кушымчалы хәл фигыльләр төп эш-хәрәкәтнең үтәлү сәбәбен (а) һәм максатын (ә) күрсәткәндә дә кулланылалар:

а) Кяғыды алып (آلوب) йегет зийадәсе илә мәсрүр улды [Акъегет, 1886, б. 4]; Бөйлә ажы ағламағы ишедеп (اشدوب) анасы керер [Акъегет, 1886, б. 6]; Муса әфәнденең йығладығыны күреп (كوروب), Нигъмәтулла әфәнде дә битәқәт булып йығлыйдыр [Бигиев, 1887, б. 14]; Әхмәди бай үткән кичдә улған ма вәқағане ишедеп (ایشدوب) киләдер иде [Бигиев, 1887, б. 16]; Қартчық қапыда кеше барлығын ишедеп (ایشدوب), утырмыш йирендән қыйам вә сөрғәтлә: «Кем бар, нә кирәк?» – дийү қапыйы ачмайа башлады [Бигиев, 1890, б. 30]; Фәридә исә, әбкәсенең жығлағанын күреп (كوروب), әүwәлгедән зийадә йәшләр дүгеп, эткәсенең муйынына қочақланып жығламайа дәвам итде [Бигиев, 1890, б. 38]; Қазанда ун сәнә торып ишетмәдегем, бәлки ишедеп дә онытдығым сүзләрне бундан ишедеп (ایشدوب) мәмнүн улмақда идем [Фәхретдин, 1899, б. 71]; Тиатро уйнаучылары, китаб вә мөәллифләре, җөмләсенең мөселман идегене хәтерләб (خاطرلب) хәйран қалыр идем [Фәхретдин, 1899, б. 76] һ.б.;

ә) Ғайниҗамал абыстайда сәне күреп чықмақыңы көтеп (كوتوب) андан қачдым [Акъегет, 1886, б. 67]; Ғабденнәсыр әфәнде Қазандан – Ғабдуллиндан туй мәсарифы өчен акча сораб (ثوراب) мәктүб йазмыш [Бигиев, 1887, б. 65]; Бән дә шул дакиқа илә үз-үземне забт идә алмадым, вә нә ичүн көлдегемне сораwыны көтмәй, берәр төрле шөбһәгә төшмәсен диб, сәбәбене бәйан итмәк улып (بیان ایتمك اولوب), Сәлимә туташға дидем: ...[Фәхретдин, 1899, б. 70].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-ып* формасындагы хәл фигыльләрне авторлар еш кына бер-бер артлы башкарылган эш-хәрәкәтләрне бирү өчен кулланалар һәм әлеге алым күпмедер дәрәҗәдә сөйләмне җанландыра торган стилистик чара максатын да үти: Господин Шубин револьверны тотқалап (توتقالاب) бақдығы wақытда кесәсендән бер кисәк балаwыз чықарып (چقاروب), зәкявәт илә, номер эчендә улан әшхасқа белдермәйенчә, мәзкүр балаwызға револьверның, дуласының очыны басып

(باصوب), револьверның зурлыгыны, биеклегене үлчәп (اولچب) алды [Бигиев, 1887, б. 58]; Җиһангир Агийев, хикәйәмезнең героинясе Маһруй кызның гыйрфанына хәйран вә хөсненә гашыйк улып (عاشق اولوب), кызы никях идеп (نكاح ايدوب) алмак фикеренә килеп (فكرينه كلوب), аталар вә кыз тарафындан разыйлык булынып (بولنوب), Җиһангирнең морадына наил вә бәхтийар улдыгы көн – бу кичәдер [Бигиев, 1890, б. 8].

Аерым очракларда бу чара авторлар тарафыннан әдәби әсәрдәге геройларның хис-кичерешләрен сурәтләгәндә кулланыла: Кечек бала исә, үз әткәсене танып (تانوب), фәрехләнеп (فرحلنوب), каршысына җөгереп килеп (جغروب كلوب): «Әткәй! Әткәй!» – дийү, кулыны вә муенындан кочаклап (قوچاقلاب), йөзене вә башыны үпмәйә башлады [Бигиев, 1890, б. 38]; Маһруй, атәш күзләре илә бүлмәнең стенасы (дивары)ны карарkән, кечек тәрәзәдә улан тимер рәшәткәйе күреп (كوروب), гвоздь зарур улмадыгыны белеп (بلوب), котырган кеше кеби гәҗәлә кылып (عجله قيلوب), җебне кулына алып (آلوب) вә бүлмәдә улан кечек өстәлне тәрәзәнең йанына килтереп (كلتروب), өстенә менеп (منوب), җебнең бер тарафыны рәшәткәйә баглап (باغلاب), питләле тарафыны муенына кийеп (كيوب), аягы илә өстәлне орып агдарып (اوروب آغداروب), әҗәлнең кулына дөшеп (دوشب), гайәт агыр мәшәкәтләр илә җан тәслим кылмайа башлады [Бигиев, 1890, б. 41].

Моннан тыш, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-ып* кушымчалы хәл фигыльләрнең редупликатив формада да кулланылу очраклары теркәлде һәм әлеге күренеш мәгънәләре ягыннан бер-берсенә якын торган, ләкин төрле тамырдан булган фигыльләрдә дә күзәтелә. Бу очракта алар *-а* кушымчалы хәл фигыльләрне алыштырып киләләр һәм мәгънәләре интенсивлык, дәвамлылык кебек төсмерләр белән баетыла: Бәс өч дуст кызышып-кызышып (قزوشوب قزوشوب) сөйләшмәкдә иделәр [Акъегет, 1886, б. 31]; Ишекләр ачылгач, җәмәгәт бер-берсене басып-кысып (باثوب قصوب), су кеби агылып, мәхкәмә эченә керә башладылар [Бигиев, 1887, б. 37]; Ике-өч дакика кәчдекдән соңра Гайшә ханым, күзендин йәшене сөртеп-себереп (سورتب – سبروب), бу тарика сүзә дәвам итде: ... [Бигиев, 1887, б. 67]; Габделгафур һәр кайулары илә мөсафәхә кылышып-күрешеп (مصافحه قيلشوب كوروشب), «Йа раббе, йәрдәм вә хәйер вир йаңа мәгыйшәт вә сәфәремә» дийәрәк, йаздыгымыз мөәззин илә бәрабәр мөтәвәккилән галәллаһ йула чыкдылар [Бигиев, 1890, б. 7]; Бүлмәгә кердегемдә Сәлимә тирләп-пешеп (تيرلب پشوب) нәрсәләрене урнашдыра иде [Фәхретдин, 1899, б. 18]; Безнең Казан байларының хатынлары, ирләре үлгәндә

үкереп-үкереп (اوكروب اوكروب) йығлап, иртәге көнендә көлә-көлә йәш кияйәгә кидәләр иде... [Фәхретдин, 1899, б. 34].

Югарыда күрсәтелгән мәгънәләрдә *-ып* кушымчалы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең тел тукымасын тәшкил иткән барлык функциональ-стиль катламнарында да (әдәби-тасвирлама, публицистик, фәнни) очрый. Биредә алар автор сөйләменең төп тел үзенчәлекләренең берсе булып торалар. Аерым алганда, мәгърифәтче язучылар аларны түбәндәге очракларда еш кулланалар:

1. Табигать күренешләрен сурәтләгәндә: Нун аwылында ике мәсҗед вар. Бер урамлы аwыл булып (بولوب), урамы озын вә киңдер. Урамы узайып (اوزايوب) қыйбла тарафындағы очында борылып (بورولوب) суға юл чықадыр [Акъегет, 1886, б. 2]; Қырда юл бәрқарар улмайып (برقرار اولميوب), қар бераз яғмыш иде. Фәқәт ачық тупрақлар да вар, шөйлә wақытларда ғарәбә илә чықсаң, көпчәк бәгзән қара кереп (كيروب), әйләнмийур [Акъегет, 1886, б. 7].

2. Көндәлек тормыш күренешләре турында язганда: Қыш әсналарында хикәйәмездә йазылынан затларның мәғыйшәтләре ғәдәтенчә кәчеп (كچوب), диккәтә лайык бер шәй йуқ иде. Белешләремез Ғали бай вә Сибғатулла әфәнде тиҗарәт илә мәшғүл улып (مشغول اولوب), бу көн Москвада, сабах үз шәһәрләрендә, у бересе көн ғайре бер мәркәзе тиҗарәтдә wақыт кәчермәкдә иделәр. Белешемез Бикбулат менла иҗарәйе wазыйфасы илә мәшғүл улып (مشغول اولوب), менлалара садақа вирмәк лязем идегене мәхәлләсенә тәүсийә вә тәнбийә идеп, аучы қуйан вә үрдәкне өмид идеп (اميد ايدوب) сақладықы кеби бу да ниқахлар өмид идеп (اميد ايدوب) сақламақда иде. Белешемез Хисаметдин менла сыбйан уқытмақдан мағада арыш вә солыларыны суқтырып (صوقتروب) вә сатып кәсеб идеп (صاتوب كسب ايدوب) эшсез һич йатмаз иде [Акъегет, 1886, б. 19].

3. Персонажларның портретын һәм хис-кичерешләрен тасвирлаганда: Йөзенә бақсаң, бу егерме биш йәшлек җегеткә тәғәҗҗебләнерсең. Йөзе гүзәл ачық. Йәнидән чықмыш кечек сақалы вә мыйықлары вә кечек сачы қоңғыр рәнкдә улып (رنكده اولوب), йөзенең гүзәллегене даха зийадәләшдерерләр. Нурлы вә күк күзләре сәтра бәсәтра сәхифәйе йөгереп (يوكروب) кичийурлар [Акъегет, 1886, б. 4]; Ошбу күп җәмәғәт арасында беркәдәр мөселман хатын вә қызлары һәм курелмәкдә иде. Бунларның йөзләренә салған челтәр пәрдәләре, йөз вә битләрене айырмачық, ушандақ нурлы вә гүзәл идеп (گوزل ايدوب) күстәрмәкдә иде…

[Фәхретдин, 1899, б. 15]; Йөзендә улған тир борчаклары энҗеләргә ошаб тезелеп (اوشاب تزلوب) торадыр иде [Фәхретдин, 1899, б. 18].

4. Персонажларның хис-кичерешләре турында сөйләгәндә: Һәр төрле тәкәллеф вә мода бәласендән азат карендәшләрем илә йәшел хәтфә (катыйфә)ләргә охшаған болынларда утырып (اوتوروب), олуғ ағач саwытлар илә кымыз эчүләремне фикерләп (فکرلب), авызымдан сулар аға иде. Койаш баткан соң төрле йакдан ишеделенәчәк курай давышларыны, көтүчеләрнең чыбыркы шартлатуларыны, чабып (چاووب) варған йулчыларның кыңғырау давышларыны, сандуғач сайрауларыны дыңлап (دڭلاب) ләззәтләнәчәк көнләрем вар идегене фикерләп (فکرلب), балалар мисалында сәвенә идем [Фәхретдин, 1899, б. 8].

5. Публицистик чигенешләрдә: Бән улайым, сез улыңыз бер фәкир, бер байғуш күрсәк, җанымыз ағрып (آغریب), кайғы хасыйл улыр. Бер хаста, хәлсез күрсәк, йәрдәм бирмәйә ғыйләҗ вә чара үғрәтмәк морад идәрез, йә үлем түшәгендә йатан бер кеше күрсәк, күземезә йәш, күңлемезә мәрхәмәт килер. Дәхи дәрдә мөбтәлә хайwан күрсәк, аҗыйып (آجیوب) ах-wах идәмез дә, бер дәгел, биш дәгел, биңләр илә дин вә дил кардәшләремез биң төрле дәрдә мөбтәлә улып (مبتلا اولوب), наданлык вә һөнәрсезлек кеби ике олуғ вә ғаддар дошманлык әленә төшеп (توشوب), җан талашдығыны күрмәйеп (کورمیوب), җанымыз тоймайып (تویمیوب), күңлемез ағламайып (آغلامیوب), ғаклымыз чаралар кыдырмайып (قدرمیوب) тордығымыз чук йазык вә тәгәҗҗеб дәгелмедер? [Акъегет, 1886, б. 5]; Бер вә нәчә мең чакрымлара сәйахлык вә сәфәр бер хәтвә – бер адым илә башландығы кеби, йаманлык да бер кечек ғөнаһ вә йаманлыкдан башланып (باشلانوب), аз-аз зийадәләнеп (زیاده لنوب), «ғөнаһе кабаир»ләр дә йиңел вә күп уладыр... Хатынларымызның да аракы вә башка мөскираты сәвәнләре йук дәгел, әмма «Гөнаһе кәбаир» улан бу йаманлык вә фәсадымыз бердән килеп (کلوب) өстемезә дөшмәделәр. Ана карыныннан бөйлә исерек вә сәрхуш туғмадык. Аз-аз бер кечек шәйдән башланып (باشلانوب), әйтдегем кеби, йаманлыкларымыз күпләнеп вә куәтләнеп (کوبلنوب و قوةلنوب), бәрәкәт күтәрелде [Бигиев, 1890, б. 6-7]; Шәкердләр вә мәдрәсә хакында бу сүзләре йазудан максудымыз – ғайреләрнең косурларыны фаш идеп, үземезе йырак күрүче вә белүче күстәрмәк дәгел, мәдрәсәләрнең рәисләре мәдрәсәләре лязем низам вә канун күстәреп (کوستروب) вә тәхсил кылынмыш ғыйлемдән хисаб алып (حساب آلوب), бу кеби толлабәләре башдан карап (قراب) йахшы тәрбийә кылмайа ғайрәт идеп (غیرت ایدوب), үйлә тарикы һәлакәтдә улан уғланлары мәдрәсәләрдә тотмаса-

лар да йахшы улыр иде [Бигиев, 1890, б. 49]; Ун йыллар тәхсил идеп (تخصيل ايدوبده) дә һәм Қазанның беренче дәрәҗәдә шөһрәт мәдрәсәсендә тәрбийәләнеп (تربيه لنوب), бер қыз қәдәр сүзләй алмадығым олуғ ғайеб вә бийүк кимчелек иде. Бәгзе бер кемсәнәләрнең, үзләренең ир җенесеннән улмақлары илә мәдехләнеп (مدحلنوب), хатынларны кимсетеп (كيمستوب) сүзләдекләрене хәтерләп (خاطرلب), бу сүзләрне үземнең хәзерге хәлем илә үлчәдегемдә нә қәдәр хата вә қоры лаф идеген йахшы аңлап (آڭلاب), бер көләсем, бер ачуым киләдер иде [Фәхретдин, 1899, б. 21].

6. Фәнни стиль катламында: ...Қазанда йөз биңдән зийадә җан хисабы улып (اولوب), дүртенче өлеше әхле исламдыр. Мөселманлар җөмләсе сөнни вә Әбу Хәнифә мәзһәбендә улып (اولوب), делләре һәм төрекчәдер. Ғоләмә вә шәкердләре чапан вә чалма кийеп (كييوب), сәүдәгәре өстендә сукна бишмәт, чалбар, қаракүл бүрек уладыр. Хатынлары қалпақ, тақыйа, читек, кәwеш кийеп (كييوب), урамға чықдықларында чапан бөркәнәләр [Фәхретдин, 1899, б. 3]; Бу елғаны йунанлылар, Төнге Мохит диңгезендән килеп (كيلوب) Әстерхан диңгезенә қушылдығыны иғтиқад идеп (اعتقاد ايدب) исемене дә «Ра» димешләр имеш. Руслар исә «Волга» исемене вирмешләр. Әмма безем бабаларымыз, иске Болғар төрекләре «Итил» дийә йад идәрләр имеш, вә бу исем арамызда хәзерге заманаға қәдәр қалмышдыр. Болғарлардан ишедеп (ايشدوب) ғарәбләр һәм «Итил» дия истиғмаль идәрләр имеш [Фәхретдин, 1899, б. 22]; ...Болғар шәһәре илқ заманларда мәшһүр бер шәһәр иде. Олуғ базары вә сәүдәсе улып (اولوب), хәтта ки ғарәб кәрваннары килер иде. Болғар халықлары Германия, Швеция, шимали Россия, Сибирийә мәмләкәтләренә сәфәр идеп (سفر ايدوب) сәүдә қылырлар иде [Фәхретдин, 1899, б. 28]; ...Болғар халқы төрек нәселендәндер, ләкин һиҗрәтдән алты йөз йыл соңында бу мәмләкәткә килгән татарлар сәбәбендән Болғарларның дәүләтләре бетеп (بتوب), бәхетләре түбән кидеп (توبان كيدوب), әүwәлге рәваҗлары юғалмыщдыр. Болғарлылар, ғалиб улған татарлар илә қатышып (قاتشوب), татарлар һәм үзләре бетдекләре хәлдә исемләрен қалдырмышлардыр. Читдән килеп (كيلوب) ғалиб улған соң, мәғлүб қаwем арасына кереп (كروب) йуғалдықлары хәлдә, исемләрене қалдырдықларына мисал уларақ ғилме тарихда күп мәртәбә тәсадеф иделенәдер [Фәхретдин, 1899, б. 29].

Шуның белән бергә *-ып* кушымчалы хәл фигыльләрнең персонажлар сөйләмендә дә кулланылуы күзәтелә:

...

– Килешсә, пәк хуп, – диде ялған венгр.

– Пәк килешә, бән буны ырақ ғизләрмен вә хилвәтчә йөзегеңне чықарып (چقاروب) кийеп вә бақып (كيوب و باقوب) сәне ядыма алып (يادمه آلوب) шадланырмын... [Акъегет, 1886, б. 28];

...

– Зәүҗем қайтмадымы икән, сән, абыстай, зинһар, бүген кемгә дә белдермәйенчә белеп (بلوب) килсәнә, ирем қайтмадымы икән? Ух!!

– Йахшы, бәбкәм, йахшы, қызым, белеп (بلوب) қайтырмын ... Менә мән өйемдә узған йылда да бер қыз бала туғдырған иде. Аның баласын мунчаға (хәммам) алып (آلوب) бардым да, мунчаға кергәч, җуынғаччабынғач бала бик йығлый башлаған иде, мунча эчендә бер қарчықға: «Абыстай, зинһар, шул баланы қулында тотып (توتوب) торсана, мин әнкәсене чағырайым», – дийә, баланы қарчықға виреп (ويروب), мунчадан чығып (چغوب), тиз-тиз кийемләремне кийеп чығып (كيوب چغوب) китдем. Әл дә бу көнә қәдәр баланың әнкәсене чақырып (چاقروب) килтерәм... [Бигиев, 1890, б. 19–20].

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-ып* кушымчалы хәл фигыльләр ярым чәчмә, ярым тезмә формада иҗат ителгән дастаннарда, шигъри әсәрләрдә, газета текстларында һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә кулланылалар [Шамарова, 1990, с. 79; Юсупов, 2006, с. 123–126; Миннуллин, 2012, с. 201–202; Абдулхаков, 2007, с. 21–22]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норманың бер күрсәткече булып торалар.

*-а* кушымчалы хәл фигыльләр. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләре текстларында *-а* кушымчалы хәл фигыльләр сирәк һәм нигездә М. Акъегет, Р. Фәхретдин әсәрләрендә кулланылалар. Биредә алар хәзерге татар әдәби телендәге кебек нигезләре тартыкка тәмамланган фигыльләргә *-а/-ә* (ا-/ه-), ә нигезләре сузыкка тәмамланган фигыльләргә *-ый/-и* (ى-) кушымчалары ялганып ясалалар: детри-детри вә қурқа-қурқа (دترى دترى و قورقا قورقا) [Акъегет, 1886, б. 25], көлә-көлә (كوله كوله) [Акъегет, 1886, б. 28], сүзләшәсүзләшә (سوزلشه سوزلشه) [Акъегет, 1886, б. 33], сөйләшә-сөйләшә (سويلشه سويلشه) [Акъегет, 1886, б. 45], шығырдый-шығырдый (شغردى شغردى) [Акъегет, 1886, б. 51], қурқа-қурқа (قورقا قورقا) [Акъегет, 1886, б. 57], йөгерә-йөгерә (يوكره يوكره) [Фәхретдин, 1899, б. 14], көлә-көлә (كوله كوله) [Фәхретдин, 1899, б. 34] һ.б.

Хәзерге татар әдәби телендә *-а* кушымчалы хәл фигыльләр төп фигыль белән белдерелгән эш-хәрәкәтнең бер вакытта яки аннан алда

башкарылуы мәгънәсе фонында аның үтәлү рәвешен яисә сәбәбен белдерәләр һәм, гадәттә, кабатланган хәлдә кулланылалар. Кайбер очракларда алар төп эш-хәрәкәтнең үтәлү вакытын яки аның максатын да ачыклап киләләр [Татар грамматикасы, 2002, 295–296; Тумашева, 1978, б. 152–154; Хисамова, 2006, б. 260–261].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-а* кушымчалы хәл фигыльләр автор сөйләмендә генә очрыйлар. Язучылар аларны нигездә төп эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен тасвирлаганда кулланалар: Хисаметдин менла кемсәйә белдермәйеп, гүйә гизмәк нийәте илә бағчайа чықды вә мәрқум қазықның йанына килеп детри-детри (دترى دترى) вә қурқа-қурқа (قورقا قورقا) ташны күтәреп астда мәктүб табды [Акъегет, 1886, б. 25]; Хәнифә туташ көлә-көлә (كوله كوله) кийәр [Акъегет, 1886, б. 28]; Бу өч дуст сүзләшә-сүзләшә (سوزلشه سوزلشه) чуқ wақыт утырдылар [Акъегет, 1886, б. 33]; Сөйләшә-сөйләшә (سويلشه سويلشه) йәшләр бер ханә янына йитешеп ғарәбәдән төшделәр [Акъегет, 1886, б. 45]; Пароход хезмәтчеләренең ашығып нәрсә ташулары, йағмур күрелгәндә ашлық уручыларның йөгерә-йөгерә (يوكره يوكره) көлтә җыймақларыны искә төшерә иде [Фәхретдин, 1899, б. 14] һ.б.

Күп кенә очракларда *-а* кушымчалы хәл фигыльләрнең, бер үк җөмләдә кабатлаулардан котылу өчен, *-ып* кушымчалы хәл фигыльләр белән бергә кулланылуы күзәтелә: Безнең Қазан байларының хатынлары, ирләре үлгәндә үкереп-үкереп еғлап (اوكروب اوكروب يغلاب), иртәге көнендә көлә-көлә (كوله كوله) йәш кийәүгә кидәләр иде... [Фәхретдин, 1899, б. 34]; Қартчығы исә йәш wақытында абыстайға ир балалар илә берлекдә сабақға йөреп (يوروب), абыстайның чыра күтәреп (كوتاروب) дә: «Уқыңыз! Үтерермен!..» дигән сүзенә қаршы шайан малайларың артдан торып (طوروب), көлә-көлә (كوله كوله): «Һич үтермәз, бу хөкемсез йир дәгел, қурықмаңыз!..» – дигән сүзләрендән ғибрәт алып (عبرت آلوب), һичнәрсә уқымамыш иде [Фәхретдин, 1903, б. 47]; Уфа, Пермь, Оренбург, Самара губерналарындан жыйылмыш улан бу матрослар, хәлләре қәдәр садақаларыны Ғаббас мелланың алдына қуйып (قويوب), пароходларына йөгерә-йөгерә (يوكره يوكره) китделәр [Фәхретдин, 1903, б. 126].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә сөйләм теле өчен хас булган *-а* кушымчалы хәл фигыльләрнең сирәк очравы аның әдәби кулланылышка яңа керә башлавы һәм мәгънәләренең күпчелек очракта башка хәл фигыльләр, аерым

алганда иске татар әдәби теленең традицион үзенчәлекләреннән саналган *-ып* һәм госманлы төрек теле өчен хас булган *-арак* кушымчалы хәл фигыльләр ярдәмендә белдерелүе белән аңлатыла.

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-а* кушымчалы хәл фигыльләр газета текстларында гына кулланылалар [Миннуллин, 2012, с. 202]. Башка язма чыганаклар өчен алар хас түгел. Нәтиҗә ясап әйткәндә, *-а* кушымчалы хәл фигыльләр бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алмыйлар һәм функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*-гач* кушымчалы хәл фигыльләр. Сөйләм теле үзенчәлеге саналган *-гач* кушымчалы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасында, нигездә, З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә», «Гөнаһе кәбаир» әсәрләрендә кулланылалар. Моннан тыш алар берникадәр дәрәҗәдә М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында очрыйлар. Р. Фәхретдиннең әсәрләрендә *-гач* кушымчалы хәл фигыльләрнең бары тик аерым кулланылыш очраклары гына теркәлде. Сәяхәтнамәләр өчен алар хас түгел.

Чыганакларда *-гач* кушымчалы хәл фигыльләр хәзерге татар әдәби телендәге кебек *-гач/-гәч* (-غاچ/-كاچ/-گاچ), *-қач/-кәч* (-قاچ/-كاچ) кушымчалары ярдәмендә ясалалар: уқығач (اوقوغاچ) [Акъегет, 1886, б. 14], беленгәч (بلنكاچ) [Акъегет, 1886, б. 26], кәчкәч (كچكاچ) [Акъегет, 1886, б. 27], күмгәч (كومكاچ) [Акъегет, 1886, б. 32], булғач (بولغاچ) [Акъегет, 1886, б. 33]; қайтқач (قايتقاچ) [Акъегет, 1886, б. 59], чыққач (چققاچ) [Акъегет, 1886, б. 68], сөаль қылғач (سؤال قلغاچ) [Бигиев, 1887, б. 5], ишеткәч (اشتكاچ) [Бигиев, 1887, б. 10], сорашқач (صوراشقاچ) [Бигиев, 1887, б. 11], сөйләгәч (سويلكاچ) [Бигиев, 1887, б. 13], кергәч (كركاچ) [Бигиев, 1887, б. 19], алғач (آلغاچ) [Бигиев, 1887, б. 24], ултырғач (اولترغاچ) [Бигиев, 1887, б. 26], қушқач (قوشقاچ) [Бигиев, 1887, б. 27], тәмам иткәч (تمام ايتكاچ) [Бигиев, 1887, б. 29], ишеткәч (اشتكاچ) [Бигиев, 1890, б. 13], җуынғач-чабынғач (جونغاچ چابنغاچ), [Бигиев, 1890, б. 19], таң атқач (طانك آتقاچ) [Бигиев, 1890, б. 24], разый улғач (راضى اولغاچ) [Бигиев, 1890, б. 33], башлағач (باشلغاچ) [Бигиев, 1890, б. 35], чықарғач (چقارغاچ) [Бигиев, 1890, б. 35], тәгриф қылғач (تعريف قلغاچ) [Бигиев, 1890, б. 44], барғач (بارغاچ) [Бигиев, 1890, б. 46], бу шәһәргә килгәч (كلگاچ) [Фәхретдин, 1899, б. 41], мәғлүм сәғәте йиткәч (يتكاچ), шиғерне күргәч (كوركاچ) һ.б.

Хәзерге татар әдәби телендә *-гач* кушымчалы хәл фигыльләр җөмләдә төп фигыльдән алда башкарылган эш-хәрәкәтне белдереп,

аны үтәлү вакыты ягыннан ачыклап килә [Татар грамматикасы, 2002, б. 296–297; Тумашева, 1978, б. 154; Хисамова, 2006, б. 261–262]. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә дә алар башка эш-хәрәкәтнең башкарылу вакыты ягыннан башлангыч ноктасын күрсәткәндә һәм, нигездә, автор сөйләмендә кулланылалар: Һәр насыл исә дә, икенче көн бай мәҗлесендә Хисаметдин менла да булынды вә бай анасының үлдегендән соңра қырық кичә кичдеге үзәрә Бикбулат менла Қоръәне кәримдән бераз уқығач (اوقوغاچ), софрайа чәй китерелде [Акъегет, 1886, б. 14–15]; Икенче мәктүб ирешдекдән өч көн соңра көн урталары кичкәч (كچكاچ), Хәнифә туташ кечек бүлмәдә тирәзә төбендә тегеш тегеп утырыр иде [Акъегет, 1886, б. 27]; «Бу мәқтүләнең иң әүwәл үлтерелдекене кем белмеш?» – дийү следователь сөаль қылғач (سؤال قلغاچ), хуҗа әфәнде: «Гурнични-хадимә белмеш», – диде [Бигиев, 1887, б. 5]; Кофе тәмам улғач (تمام اولغاچ), Муса әфәнде господин Андреевдән китде [Бигиев, 1887, б. 24]; Сәүдә хезмәтләрем тәмам улғач (تمام اولغاچ) вә үзем бөтен-бөтенә сәламәтләнеп йиткәч (سلامتلنوب يتكاچ), Қазанға қайтырмын [Бигиев, 1890, б. 17]; Икенче бүлмәйә кергәч (كركاچ), қызы Фәридәне күрде [Бигиев, 1890, б. 38]; Үз күлмәкләремне үзем тегәдер идем, бу шәһәргә килгәч (كلگاچ), хуҗа хатыныңдан ойық бәйләргә үгрәндем [Фәхретдин, 1899, б. 41]; Мәғлүм сәғәте йиткәч (يتكاچ), хадимләр килеп, әдәб илә әгаһ қылурлар вә бән дә қайтып кидәр идем [Фәхретдин, 1899, б. 76]; Шиғерне күргәч (كوركاچ), Закирең диде өлкәнләр дә, һай! [Фәхретдин, 1903, б. 21] һ.б.

Аерым очракларда *-гач* кушымчалы хәл фигыльләр төп фигыльдән аңлашылган эш-хәрәкәтнең үтәлү сәбәбен белдереп киләләр: Ғабденнәсыр әфәнде прокурорға бу җаwабны виргәч (ويركاچ), господин Андреев бик шадланды [Бигиев, 1887, б. 41]; Бу сүзләрне Муса әфәндедән ишеткәч (اشتكاچ), һәб җәмәғәт мөтәхәйер улдылар [Бигиев, 1887, б. 45]; Сатылачақ нәрсәләр вә ақча тәмам улғач (تمام اولغاچ), Ғабделғафур әфәнде ... Мәмәт әфәнде янына тормайа күчде [Бигиев, 1890, б. 51] һ.б.

Чыганакларда еш кына *-гач* кушымчалы хәл фигыльләр бер җөмләдә *-ып* кушымчалы хәл фигыльләр белән бергә кулланылалар. Бу очракта алар бер-бер артлы башкарылган эш-хәлләрне белдереп киләләр. Алда әйтеп үткәнчә, хәл фигыльләрнең бу рәвешле кулланылышы сөйләмдә кабатлаулардан коткара: Ғайниҗамал абыстай кәндесене ғайебләмәсенләр ичүн шөйлә иғлан итде ки, Хәнифә

туташ дүнке көн килеп (كلوب), бераз торып (توروب), Хисаметдин менла чыккач (چققاچ) ғаиб улды имеш [Акъегет, 1886, б. 68]; Ғабденнәсыр әфәнделәр кереп ултырғач (كروب اولترغاچ), дүрт-биш дәқиқа кичдекдән соңра, бер исерек рус чәйханәйә кереп (كروب), Ғабденнәсыр әфәнделәрнең өстәлендән бер-ике өстәл аша бер өстәл йанына ултырып (اولتروب), чәйханә хадимендән мөскир ғарақы таләб идийур [Бигиев, 1887, б. 47]; Ғалийевнең китдеге бәғдендә ике сәғәт миқдар wақыт кичкәч (كچكاچ), кичәнең ғайәт қараңғылығы улғач (اولغاچ), қарчық, өйдән чығып (چغوب), туғры Қабан күленә тәвәҗҗеһләнде [Бигиев, 1890, б. 33] һ.б.

Сөйләм теле өчен хас булган *-гач* кушымчалы хәл фигыльләрнең XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең барысында да кулланылмавы аның әдәби кулланылышка яңа керә башлавы һәм мәгънәләренең күпчелек очракта *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр һәм *соңра* бәйлегеннән торган грамматик конструкцияләр ярдәмендә белдерелүе белән аңлатыла.

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-гач* кушымчалы хәл фигыльләр ярым чәчмә, ярым тезмә формада иҗат ителгән дастаннарда, шигъри әсәрләрдә, газета текстларында кулланылалар [Шамарова, 1990, с. 79; Юсупов, 2006, с. 128; Миннуллин, 2012, с. 202]. Дини-фәлсәфи хезмәтләр өчен алар хас түгел. Нәтиҗә ясап әйткәндә, *-гач* кушымчалы хәл фигыльләр бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алмыйлар һәм функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*-кән (икән)* кушымчалы хәл фигыльләр. Төрек теле үзенчәлеге саналган *-кән (икән)* кушымчалы хәл фигыльләр фигыльләрнең заман формаларына *икән* ярдәмче фигыленең кыскаруы нәтиҗәсендә барлыкка килгән *-кән* (كن-) кушымчасы ялганып ясалалар [Кононов 1956, с. 484–485]. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә аларның нигездә *-р* кушымчалы билгесез киләчәк заман хикәя фигыльләреннән ясалган формалары кулланыла: кидәркән (كيدركن) [Акъегет, 1886, б. 20], кидәрләркән (كيدرلركن) [Акъегет, 1886, б. 44], истәркән (استركن) [Акъегет, 1886, б. 52], барыркән (باروركن) [Бигиев, 1887, б. 16], сөкүт идәркән (سكوت ايدركن) [Бигиев, 1887, б. 45], ултырырларкән (اولتروولركن) [Бигиев, 1887, б. 49], сөйләшерләркән (سويله شورلركن) [Бигиев, 1887, б. 58], тәфтиш идәркән (تفتيش ايدركن) [Бигиев, 1887, б. 58], қуйаркән (قويركن) [Бигиев, 1887, б. 58], вирeркән

(ويروركن) [Бигиев, 1890, б. 5], йабаркән (يباركن) [Бигиев, 1890, б. 16], алыркән (آلوركن) [Бигиев, 1890, б. 17], чығаркән (چغاركن) [Бигиев, 1890, б. 27], дәwам идәркән (دوام ايدركن) [Бигиев, 1890, б. 30], кереркән (كرركن) [Бигиев, 1890, б. 30], қараркән (قراركن) [Бигиев, 1890, б. 41] һ.б.

Шул ук вакытта бередә әлеге хәл фигыльнең *-мыш* кушымчалы билгесез үткән заман хикәя фигыль нигезендә ясалган формасы да теркәлде: утырмышкән (اوتورمشكن) [Акъегет, 1886, б. 12].

*-ркән* кушымчалы хәл фигыльләр функцияләре һәм мәгънәләре ягыннан хәзерге татар әдәби телендәге *-ганда* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең, *-ган wакытта* конструкцияләренең грамматик синонимнары булып торалар. Алар җөмләдәге төп фигыль белән бер үк вакытта башкарыла торган процессны белдереп, аннан аңлашылган эш-хәрәкәтне үтәлү вакыты ягыннан ачыклап киләләр [Кононов 1956, с. 485]. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә дә алар әлеге максатта кулланылалар: Бөйлә кидәркән (كيدركن) йәш қыз бер дөққяна керде [Акъегет, 1886, б. 20]; Хәтта ки бер эт йул аша узмақ истәркән (استركن) өлгермәйеп, колясканың көпчәкләре астында қалып уртаға йарылып, эчәкләре һаwаны бераз исләтделәр [Акъегет, 1886, б. 52]; Бу тарика господин Шубин бақышы илә мәзкүр өстәлне диққать илә тәфтиш идәркән (تفتيش ايدركن), өстәл өстендә алтын илә мөзәййән бер револьвер күрде [Бигиев, 1887, б. 58]; Господин Шубин илә Иванов номер эченә кергәч, Иванов, қулындан чемодан, мендәрләрне номер идәненә қуйаркән (قويركن): «Менә бән сезнең килүеңезгә қәдәр номерне дә арытмадым, җыймадым», – диде [Бигиев, 1887, б. 60]; Ибраһим әфәнде қартчығы қурқытмайа дәвам идәркән (دوام ايدركن) өйнең қапысыны қақмайа башладылар [Бигиев, 1890, б. 30]; Бу хәбәрләр һәр қайусы хата булырлар дийү Җиһангир, үз-үзенә тәсалла вирееп, тәғҗилән өй эченә кереркән (كرركن), Маһруйның әнкәсе Җиһангирә раст килде [Бигиев, 1890, б. 37] һ.б.

*-мышкән* формасы исә төп эш-хәрәкәт алдыннан башкарылган процессны белдерә, ягъни *-гач* кушымчалы хәл фигыльләрне алыштырып килә: Ғали бай ғаиләсе илә чәй эчмәгә утырмышкән (اوتورمشكن), Бикбулат менла әфәнде керде [Акъегет, 1886, б. 12].

Госманлы төрек теле өчен хас булган *-кән (икән)* кушымчалы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы язма чыганакларыннан татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә генә кулланылалар. Бу аларның әдәби телдә гомумкулланылышка кереп китә алмавы һәм мәгънәләренең күпчелек очракта *-ган, -дық* кушымчалы сыйфат

фигыльләр һәм *wақыт, заман* сүзләреннән торган грамматик конструкцияләр ярдәмендә белдерелүе белән аңлатыла. Нәтиҗә ясап әйткәндә, *-кән (икән)* кушымчалы хәл фигыльләр бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма текстларда да урын алмыйлар һәм функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*-арак* кушымчалы хәл фигыльләр. Төрек теле өчен хас булган *-арақ* кушымчалы хәл фигыльләр З. Бигиев һәм Ф. Кәрими сәяхәтнамәләренең төп тел үзенчәлеген тәшкил итә. Башка әсәрләрдә алар сирәк кулланылалар. Әлеге хәл фигыльләр *-(й)арақ/-(й)әрәк* (-ارق/-ه رق/-ه رك/-رك) кушымчасы ярдәмендә ясалалар: тамаша идәрәк (تماشا ايدرك) [Акъегет, 1886, б. 9], тәбәссем идәрәк (تبسم ايده رك) [Бигиев, 1890, б. 30], гизәрәк (گيزه رك) [Бигиев, 1908, б. 12], мөсафәхә идәрәк (مصافحه ايده رك) [Бигиев, 1908, б. 17], миһман уларақ (مهمان اولارق) [Бигиев, 1908, б. 22], мөкәфәт қыларақ (مكافات قيلارق) [Бигиев, 1908, б. 77], өмид идәрәк (اميد ايده رك) [Бигиев, 1908, б. 85], wасыл уларақ (واصل اوله رق) [Кәрими, 1902, б. 7], бақарақ (باقه رق) [Кәрими, 1902, б. 20], кисәрәк (كسه رك) [Кәрими, 1902, б. 31], гизәрәк (كزه رك) [Кәрими, 1902, б. 34], күстәрәрәк (كوستره رك) [Кәрими, 1902, б. 44], дулашарақ (طولاشه رق) [Кәрими, 1902, б. 52], бағланарақ (باغلانه رق) [Кәрими, 1902, б. 85], күндәреләрәк (كوندريله رك) [Кәрими, 1902, б. 98], тәшәккерләр идәрәк (تشكرلر ايده رك) [Кәрими, 1902, б. 124], сүз ачыларақ (آچيله رق) [Кәрими, 1902, б. 145], бинәрәк (بينه رك) [Кәрими, 1908, б. 14], тәрҗемә идәрәк (ترجمه ايدره ك) [Кәрими, 1908, б. 16], чумарақ (چوماره ق) [Кәрими, 1908, б. 19], үртәрәк (اورته رك) [Кәрими, 1908, б. 23], чықарақ (چيقاره ق) [Кәрими, 1908, б. 30], истифадә идәрәк (استفاده ايده رك) [Кәрими, 1908, б. 43] һ.б.

Нигезе сузыкка тәмамланган фигыльләрдә хәл фигыль кушымчасы алдыннан интервокаль [й] тартыгы өстәлә: дийәрәк (ديه رك) [Бигиев, 1890, б. 67], уқыйарақ (اوقويه رق) [Кәрими, 1902, б. 5], қуйарақ (قويه رق) [Кәрими, 1902, б. 64], йықайарақ (ييقايه رق) [Кәрими, 1902, б. 67], эстәйәрәк (ايستيه رك) [Кәрими, 1902, б. 93], уйуйарақ (اويويه رق) [Кәрими, 1902, б. 165], сулайарақ (صولايه رق) [Кәрими, 1902, б. 180], йәшәйәрәк (يشايه رك) [Кәрими, 1908, б. 26], башлайарақ (باشلايه رق) [Кәрими, 1908, б. 27] һ.б.

Әлеге күренеш *-арақ* кушымчалы хәл фигыльләрнең юклык формасында да күзәтелә: илтифат итмәйәрәк (التفات ايتميه رك) [Бигиев, 1908, б. 103–104], үлмәйәрәк (اولميه رك) [Кәрими, 1902, б. 148], ғәмәл итмәйәрәк (عمل ايتميه رك) [Кәрими, 1908, б. 18], риғәйәт итмәйәрәк

(رعايت ايتميه رك) [Кәрими, 1908, б. 22], аңламайарак (آڭلاميه رق) [Кәрими, 1908, б. 48], билмәйәрәк (بيلمه رك) [Кәрими, 1908, б. 50] һ.б.

Функциясе һәм мәгънәсе ягыннан *-арақ* кушымчалы хәл фигыльләр билгеле бер дәрәҗәдә *-ып* һәм *-а* кушымчасы алган хәл фигыльләрнең грамматик синонимнары булып торалар. Алар җөмләдәге төп эш-хәрәкәт белән бер үк вакытта яисә аннан алда башкарылган процессны белдереп, төп эш-хәрәкәтне үтәлү рәвеше ягыннан ачыклап килəләр [Кононов 1956, с. 477]. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә дә бу хәл фигыльләр әлеге мәгънәләрендә кулланылалар: Бу инчә биле тамаша (تماشا ايدرك) идәрәк менламыз хәйратда қалды, мәғыйшәтнең зәхмәтләрене оныдып үз-үзене онытды [Акъегет, 1886, б. 9]; Бундан соңра Нева җаддәсендә буйдан-буйа бер гизәрәк (كزه رك) Петербурғың гәҗә wақытындағы манзарасыны сәйер вә тамаша итдек [Кәрими, 1902, б. 34]; Башқа бер көн бер даха киләҗәк улып, музәдән чықарақ (چيقاره ق) нәфәсемезе қаһвәханәдә алдық [Кәрими, 1902, б. 76]; Ағачларыны, йулларыны вә чайырларыны фән вә сәнғәт йәрдәме илә тәрбийә идәрәк (تربيه ايده رك) үйлә бер хәлә китермешләрдер ки, ғаҗәиб табиғатә вә ғарибе халиқатә даир нә қәдәр ләтафәт күрмәк истәрсәң, бурада вардыр [Кәрими, 1902, б. 124–125]; Бозаулық вокзалына йитдегемездә вагондан чықдығым кеби һәр икесе платформада гизәрәк (كزه رك), бәне бақыйурлар иде [Кәрими, 1908, б. 8]; Иләредәге ир илә хатын, вә артдағы ике қыз һәб үз араларында сөйләшәрәк (سويله شه رك) ғайәт кибаранә вә әдибанә бер сурәтдә гизмәкдәләр иде [Кәрими, 1908, б. 55]; Җамиға махсус бераз әүwәл варарақ (واره رق) һәр тарафы бақдық [Кәрими, 1908, б. 67] һ.б.

Чыганакларда еш кына *-арақ* кушымчалы хәл фигыльләрнең бер үк җөмләдә *-ып* кушымчалы хәл фигыльләр белән бергә кулланылуы күзәтелә. Бу очракта алар бер-бер артлы башкарылган эш-хәрәкәтләрне белдереп киләләр. Әлеге чара җөмләдә бер үк форманың кабатлануыннан коткара: Мәйетәнең тиресенә қәнәғәт қылмай, симезлегене күреп (كوروب), кәндем буғазладым дийәрәк (ديه رك), Субаш мөселманларына шу мәйетәйе сатып (صاتوب) йидермеш [Бигиев, 1908, б. 21]; Билет алып (آلوب) багажлары тәслим идәрәк (تسليم ايده رك) әшйамызы вагона йирләшдердекдән соңра чуқ тормады, икенҗе ишарәт вирелде [Кәрими, 1902, б. 4]; Кәндесе илә күрешеп (كوريشوب) берабәр җамиға керәрәк (كيره رك) намаз қылдық [Кәрими, 1902, б. 16]; Мөғәллимләр кәнделәренең кечек-кечек шәкертләренә хайванлары вә қошлары күстәрәрәк (كوستره رك) дәрес виреп (درس ويروب) гизмәкдә иделәр

[Кәрими, 1902, б. 73]. Сызраньда ике сәгәт қәдәр торып (طوروب), башқа вагонлара бенәрәк (بينه رك), сәгәт 7дә хәрәкәт итдек [Кәрими, 1908, б. 14]; Қырымдан дышары чықып (چيقوب) Русия мәмләкәтләренә киләрәк (كله رك), рус вә йәһүди дилбәрләрене күрдекдә, бунларың әксәре ... әхлақсызлық вә сәфаһәтә, вә даһа зийадәсенә дучар улыйурлар [Кәрими, 1908, б. 38–39]; Бән дә һәрбере илә күрешәрәк (كوريشه رك), илтифатларына тәшәккер итдектән соңра, рәфиқым Хәмитҗан әфәндейе анлара тәқдим идеп (تقديم ايدوب) таныштырдым [Кәрими, 1908, б. 56].

Госманлы төрек теле өчен хас булган *-арақ* кушымчалы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы язма чыганакларыннан татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә [Абдулхаков, 2007, с. 22] генә кулланылалар. Бу аларның әдәби телдә гомумкулланылышка кереп китә алмавы һәм мәгънәләренең күпчелек очракта *-ып, -а* кушымчалы хәл фигыльләр ярдәмендә белдерелүе белән аңлатыла. Нәтиҗә ясап әйткәндә, *-арақ* кушымчалы хәл фигыльләр бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма текстларда да урын алмыйлар һәм функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*-ынча* кушымчалы хәл фигыльләр. Төрек теле үзенчәлеге саналган *-ынча* (-ينچه) кушымчалы хәл фигыльләр нигездә З. Бигиевнең әсәрләрендә һәм Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә очрыйлар. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында аларның бары тик аерым кулланылыш очраклары гына теркәлде. Р. Фәхретдин әсәрләре өчен бу хәл фигыльләр хас түгел. Чыганакларда *-ынча* (-ينچه) кушымчалы хәл фигыльләрнең күпчелек очракта юклык формасы кулланыла. Барлык формасында алар сирәк очрый һәм, төп эш-хәрәкәттән алда башкарылган процессны белдереп, аны үтәлү вакыты ягыннан ачыклап киләләр: Маһруй мәктүбне йазып тәмам идәнчә (تمام ايده نچه), хатны Йағқуб Ғалийевкә тапшырмақ нияте илә қарчық да, әлбисә-кийемләрене кийеп, тәмам вә мәктүб илә өйүдән хоруж әйләде [Бигиев, 1890, б. 22].

Чыганакларда барлык формасындагы *-ынча* кушымчалы хәл фигыльләр өчен *дәк* (دك) һәм *қәдәр* (قدر) бәйлекләре белән кулланылу хас. Бу очракта алар юнәлеш килеше кушымчасын алалар. Әлеге төзелмә җөмләдә төп эш-хәрәкәтнең вакыт якыннан үтәлү чиген белдерә һәм хәзерге татар әдәби телендәге *-ганчы* кушымчалы хәл фигыльләрне [Татар грамматикасы, 2002, б. 297] алыштырып килә: Абыстай, риҗа идәрмен, менла Хисаметдин шәһәрә йитешенчәйә дәк (يتشنچه يه دك)

бәне ғизлә, кил, Алла разый улсын [Акъегет, 1886, б. 88]; Шимди исә, хәмелең тәмам уланчайа қәдәр (تمام اولانچه يه قدر), күрешергә wақыт булмас, бу кичәмез ахырғы кичәдер [Бигиев, 1890, б. 18].

*-ынча* кушымчалы хәл фигыльләрнең юклык формасы *-майынча/-мәйенчә* (-مينچه) кушымчасы ярдәмендә ясала: таралмайынча (طارالمينچه) [Бигиев, 1887, б. 4], җаwаб вирмәйенчә (خواب ويرمينچه) [Бигиев, 1887, б. 10], сөйләшмәйенчә (سويله شمينچه) [Бигиев, 1887, б. 15], йоқламайынча (يوقلاميچه) [Бигиев, 1887, б. 20], уқымайынча (اوقومينجه), ашықмайынча (آشوقمينجه) [Бигиев, 1887, б. 46], белдермәйенчә (بلدورمينچه) [Бигиев, 1887, б. 58], дормайынча (دورمينچه) [Бигиев, 1890, б. 9], кермәйенчә (كيرمينچه) [Бигиев, 1890, б. 11], кидмәйенчә (كيدمينچه) [Бигиев, 1890, б. 19], аңламайынча (انكلامينچه) [Бигиев, 1890, б. 29], қайтмайынча (قايتماينچه) [Бигиев, 1890, б. 36] һ.б.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә юклык формасындагы *-ынча* кушымчалы хәл фигыльләр *-ып* кушымчалы хәл фигыльләрнең юклык формасын алыштырып киләләр. Нигездә алар җөмләдәге төп эш-хәрәкәт белән бер вакыт яссылыгында башкарыла торган процессны белдереп, аның үтәлү рәвешен тасвирлаганда кулланылалар: Муса әфәнде бер нәрсә дә җаwаб вирмәйенчә (خواب ويرمينچه) тәфәккердә тәғәҗҗебләнеп ултырадыр [Бигиев, 1887, б. 10]; Өчесе дә сөйләшмәйенчә (سويله شمينچه) чәй эчәләр [Бигиев, 1887, б. 15]; ...сән, абыстай, зинһар, бүген кемгә дә белдермәйенчә (بلدرمينچه) белеп килсәнә, ирем қайтмадымы икән? [Бигиев, 1890, б. 19]; Әгәр дә мәнем өйемдә бала туғдырмыш улса идең, мән ул эшне бер дә сәтер қылмайынча (ستر قيلماينچه) хөкем хозурында әйтер идем [Бигиев, 1890, б. 35] һ.б.

Күп кенә җөмләләрдә хәл фигыльнең әлеге ике формасы сөйләмгә җанлылык кертү максатыннан бергә кулланылалар: Бер дәқиқа кичкәч, старшина, ашықмайынча (آشوقمينجه), борнысындағы күз көзгесене төзәтеп (توزه توب), присяжный заседательләрнең иттифақы нә идегене уқымайа башлады [Бигиев, 1887, б. 46]; Господин Шубин револьверны тотқалап бақдығы wақытда кесәсендән бер кисәк балаwыз чықарып (چقاروب), зәкәwәт илә, номер эчендә улан әшхасқа белдермәйенчә (بلدورمينچه), мәзкүр балаwызға револьверның, дуласының очыны басып (باصوب), револьверның зурлығыны, бийеклегене үлчәп алды [Бигиев, 1887, б. 58]; Бу хәбәрнең хәқыйқатене белә алмайынча (بيله آلماينچه), Җиһангир, Қазанға тәвәҗжеһләнеп (توجهلنوب), лязем қәдәр мөддәтнең кәчмәсе илә Қазанға килеп йитде [Бигиев, 1890, б. 37]; Кич улғач да,

күзенә йоқы килмәйенчә (يوقو كلمينچه), йарым кичәйә қәдәр хайли фикерләр қылып (فكرلر قيلوب), йоқламады [Бигиев, 1890, б. 40] һ.б.

Чыганакларда аерым очракларда юклык формасындагы *-ынча* кушымчалы хәл фигыльләр киләчәктә башкарылырға тиеш булган, әмма билгеле бер сәбәпләр нәтиҗәсендә тормышқа ашмаган эш-хәрәкәтнең киресен белдерү өчен кулланылалар: Энем, әгәр дә мәхкәмәдә күстәрән йазуығызны кичә бәңа йазып вирмәгән булса идең, Муса Салихов қәтелдә мәғйүб улмайынча (معيوب اولماينچه), хәлас улыр иде [Бигиев, 1887, б. 61]; Мөшфиқа әнкәйем, әгәр сез шимди бу номердә бәнем йанымда улсаңыз иде, бәлкем бән үз-үземне қәтел идмәйенчә (قتل ايدمينچه), әүwәлге кеби, дөнйада торыр идем [Бигиев, 1887, б. 69].

Госманлы төрек теле өчен хас булган *-ынча* кушымчалы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы язма чыганакларыннан татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә генә кулланылалар. Бу аларның әдәби телдә гомумкулланылышка кереп китә алмавы һәм мәгънәләренең күпчелек очракта *-дық* кушымчалы сыйфат фигыльләр һәм соңра бәйлегеннән торган грамматик конструкцияләр ярдәмендә белдерелүе белән аңлатыла. Нәтиҗә ясап әйткәндә, *-ынча* кушымчалы хәл фигыльләр бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма текстларда да урын алмыйлар һәм функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*-дықча* кушымчалы хәл фигыльләр. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә госманлы төрек теле үзенчәлеге саналган *-дықча* кушымчалы хәл фигыльләр сирәк кулланыла. Алар нигездә Р. Фәхретдиннең романнарында һәм Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә очрый. Әлеге хәл фигыльләр *-дықча/-декчә* (-دكچه/-دكجه/-دقچه/-دقجه) кушымчасы ярдәмендә ясалалар: кәчдекчә (كچدكجه), тәрәққый итдекчә (ترقى اتدكجه) [Кәрими, 1902, б. 2], дәгешдекчә (دكيشدكجه) [Кәрими, 1902, б. 87], китдекчә (كيتدكچه) [Кәрими, 1908, б. 4], улдықча (اولدقجه) [Кәрими, 1908, б. 26], форсат дөшдекчә (فرصت دوشدكجه) [Кәрими, 1908, б. 42], артдықча (آرتدقچه) [Фәхретдин, 1899, б. 5].

*-дықча* кушымчалы хәл фигыльләр билгеле бер дәрәҗәдә хәзерге татар әдәби телендә *-у* кушымчалы исем фигыльләр һәм *белән* бәйлегеннән торган конструкциянең грамматик синонимы булып торалар. Алар нигездә өзлексез башкарыла яисә кабатланып килә торган эш-хәрәкәтне белдереп, төп эш-хәрәкәтне үтәлү вакыты ягыннан

ачыклап киләләр [Кононов 1956, с. 482]. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә дә *-дыкъча* кушымчалы хәл фигыльләр әлеге мәгънәләрендә кулланылалар: Заман кәчдекчә (کچدکجه), мәдәнийәт вә мәгәриф тәрәккый итдекчә (ترقی اتدکجه) һәр шәй алмашындыгы кеби, сәйәхәт мәсьәләсе дәхи пәк чуқ тәбдил итмешдер [Кәрими, 1902, б. 2]; Заман дәгешдекчә (دکیشدکجه) зирағәт вә тиҗарәт вә сәнәғәтләрең дә ысулы вә қуанины дәгешмешдер [Кәрими, 1902, б. 87]; Бабаларымызың «Йул ғазабы гүр ғазабы» дидекләре сүзләр, китдекчә (کیتدکچه), хөқемене ғаиб идәчәкдер [Кәрими, 1908, б. 4]; Татарларың руслар илә мөнәсәбәтләренә киленҗә, татарлар, форсат дөшдекчә (فرصت دوشدکجه), Русийәйә һөҗүм илә йағма вә ғарт идәрләр иде [Кәрими, 1908, б. 42]; Әдәбле ул, халық сәвәр; ғыйффәтле ул, Аллаһы Тәғалә сәвәр; сабырлы ул, үкенмәзсән; тәхәммелле ул қартаймазсән; тәхсилең артдықча (آرتدقچه) кечелегең, белегең артдықча (آرتدقچه) сабырын артсын! [Фәхретдин, 1899, б. 5].

Моннан тыш *ул-* ярдәмче фигыленнән ясалган *-дықча* кушымчалы хәл фигыльләр авторлар тарафыннан җөмләдәге төп эш-хәрәкәтнең, яисә персонажга хас сыйфат-билгеләрнең дәрәҗәсен күрсәтү өчен кулланылалар: Қасыйм татарлары буфет, вокзал, гостиница тотмақ хосусында улдықча (اولدقجه) тәрәккый итмешләрдер [Кәрими, 1908, б. 26]; Назыр вә мотағаләсе улдықча (اولدقجه) туғрыдыр [Кәрими, 1908, б. 29–30]; Бунлар чуҗықларыны уқытмақ җәһәтенә улдықча (اولدقجه) һиммәт вә ғайрәт идийурлар [Кәрими, 1908, б. 35].

Р. Фәхретдин *-дықча* кушымчалы хәл фигыльләрне, еш кына, тартым кушымчалары белән бергә иярчен кереш җөмләләр составында куллана. Бу – автор тарафыннан әйтеләсе фикергә, эчтәлеккә өстәмә рәвештә ачыклык кертү максатыннан эшләнә: Ләкин йуқарыда дидегемезчә (دیدکمچه), халықның бунлардан хәбәре йуқ, бәлки һәркем үзе эше илә мәшғүл иде [Фәхретдин, 1899, б. 17]; Қарға йулбашчы улса, үләксәгә алып варыр дидекләренчә (دیدکلرنچه), бу кеби хатынлар үзләренең тәрбийәсендә улған мәғсүм балаларны үз эзләренә бастырырлар вә ғәдәтләренә һәм ийәртерләр [Фәхретдин, 1899, б. 66]; Бу исә йуқарыда дидегемезчә (دیدکمزچه), мәсҗед хозурында дин мәкдәбе ачып, мәхәллә баласына тәрбийә вирмәге иде [Фәхретдин, 1903, б. 14]; Ләкин йуқарыда сөйләдегемезчә (سویلدکمزچه), малы-фәләне улмадығындан Йосыф бабай химайәсенә дөшмәге лязем килде [Фәхретдин, 1903, б. 46].

Шуның белән бергә тартым кушымчасы алган *-дықча* кушымчалы хәл фигыльләрнең *-ганчы* формасы урынында кулланылу очрагы

да теркәлде: Менлалар да: «Буны вирдегенчә (ويردكنچه), бер түгәрәк бөтен ақны виргән булса, йахшы улачақ иде», – дийә сукранып кәтделәр [Фәхретдин, 1903, б. 31].

Юклык формасындагы *-дықча* кушымчалы хәл фигыльләр җөмләдәге төп эш-хәрәкәтнең башкарыла алмау сәбәбен күрсәткәндә кулланылалар: Бинаән ғаләйһи бер-беремезнең табиғәтләре вә әхлақлары анлашылмадықча (اكلاشلمدقچه) җаwабы қатғый вирмәгә мөқтәдирә дәгелмен [Акъегет, 1886, б. 26].

Госманлы төрек теле үзенчәлеге саналган *-дықча* кушымчалы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка дини-фәлсәфи хезмәтләрдә генә очрыйлар [Абдулхаков, 2007, с. 22]. Бу аларның әдәби телдә гомумкулланылышка кереп китә алмавы белән аңлатыла. Нәтиҗә ясап әйткәндә, *-дықча* кушымчалы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби теле өчен хас булган функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*-маздан* кушымчалы хәл фигыльләр. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә төрек теле үзенчәлеге саналучы *-маздан* кушымчалы хәл фигыльләр [Кононов 1956, с. 484] сирәк кулланылалар. Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләреннән кала башка язма чыганакларда аларның бары тик аерым кулланылыш очраклары гына теркәлде. Әлеге хәл фигыльләр *-маздан/-мәздән* (-مزدن/-مازدن) кушымчасы ярдәмендә ясалалар: килмәздән (كلمزدن) [Акъегет, 1886, б. 71], чықмаздан (چيقمازدن) [Кәрими, 1902, б. 2], бетмәздән (بيتمزدن) [Кәрими, 1902, б. 133], вармаздан (وارمزدن) [Кәрими, 1902, б. 159], кермәздән (كيرمزدن) [Кәрими, 1902, б. 59], тәмам итмәздән (تمام ايتمازدن) [Фәхретдин, 1899, б. 34], йитешмәздән (يتشمازدن), wақыты йитмәздән (وقتى يتمازدن) [Фәхретдин, 1903, б. 12].

Мисаллардан күренгәнчә, *-маздан* кушымчалы хәл фигыльләр нигездә төп эш-хәрәкәтне үтәлү вакыты ягыннан ачыклап, аннан соң башкарылачак процессны белдереп киләләр һәм күпчелек очракта *әүwәл, мөқәддәм* сүзләре белән бергә кулланылалар: Бундан бөйлә машина килмәздән (كلمزدن) бер сәғәт әүwәл тулы мәүқыйф татар иде [Акъегет, 1886, б. 71]; Муса Салихов Зөләйхане қәтелдә нахақ мәғйүб улдығы кеби, бәнем өчен дә кем булса мәғйүб улмасын дийү үз-үземне қәтел қылмаздан (قتل قيلمازدن) мөқәддәм, ишекне йозақ илә биклимен [Бигиев, 1887, б. 76]; Сәфәрә чықмаздан (چيقمازدن) әүwәл йул ичүн бәғзе хәзерлек күрмәк лязем улдығы һәркәсә мәғлүмдер [Кәрими, 1902,

б. 2]; Аурупада сәрбәстҗә вә һәр шәйе аңлайып гизә белмәк вә кәндеңе алдатмамақ ичүн франсызҗа, алманҗа, яхуд инглизҗә лисанлардан берене белмәк вә һәр йирә вармаздан (وارمزدن) әүwәл ул йирең харитасына бақып, рәһнамәсене моталәға итмәле [Кәрими, 1902, б. 159]; Мәғлүм заманы йитешмәздән (يتشمازدن) мөқәддәм йөк тартдырылмыш ат имгәнеп, эшдән чықтығы кеби, wақыты йитмәздән (وقتى يتمازدن) мөқәддәм сабақ уқытдырылмыш бала һәм имгәнеп қалмақдадыр [Фәхретдин, 1903, б. 12].

Аерым очракларда *-маздан* кушымчалы хәл фигыльләр билгеле бер сәбәпләр нәтиҗәсендә башкарылмыйча калган эш-хәрәкәтне белдерү өчен дә кулланылырга мөмкин: Ана деле улған фарсычаны Тыйһранда уқып, соңра Мисыр Әл-Қаһирәгә вармыш, анда исә қызлар дарелфөнүнендә биш ел уқымыш; ғарәб, француз, инглиз делләрене мөкәммәл сурәтдә белмеш, қул һөнәрләрене, йорт итмәк вә мәғыйшәт қылмақ ғыйлемләрене гүзәл үгрәнмеш; ләкин дарелфөнүн тәхсилене тәмам итмәздән (تمام ايتمازدن) мөқәддәм Тыйһранға қайтырға мәҗбүр улмыш имеш [Фәхретдин, 1899, б. 34].

Госманлы төрек теле үзенчәлеге саналган *-маздан* кушымчалы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә генә очрыйлар. Башка язма чыганаклар өчен алар хас түгел. Бу әлеге хәл фигыльләрнең әдәби телдә гомумкулланылышка кереп китә алмавы белән аңлатыла. Нәтиҗә ясап әйткәндә, *-маздан* кушымчалы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби теле өчен хас булган функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*-мадан* кушымчалы хәл фигыльләр. Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә, башка мәгърифәтче язучыларның әсәрләреннән аермалы буларак, төрек теле өчен хас булган *-мадан* кушымчалы хәл фигыльләрнең кулланылуы күзәтелә. Алар *-мадан/-мәдән* (-مه دن) кушымчасы ярдәмендә ясалалар: йазмадан (يازمه دن) [Кәрими, 1902, б. 45], күрмәдән (كورمه دن) [Кәрими, 1902, б. 114], қонушмадан (قونوشمه دن), танышмадан (طانيشمه دن) [Кәрими, 1902, б. 143], бетмәдән (بيتمه دن) [Кәрими, 1902, б. 149], тойылмадан (طويولمادن) [Кәрими, 1908, б. 21], китмәдән (كيتمه دن) [Кәрими, 1902, б. 24] һ.б.

Әлеге хәл фигыльләр башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен һәм вакытын ачыклап киләләр һәм билгеле бер дәрәҗәдә юклык формасындагы *-арак* кушымчалы хәл фигыльләрнең грамматик синонимнары булып торалар [Кононов 1956, с. 483]. Чыганакларда әлеге

хәл фигыльләр башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен тасвирлаганда кулланылалар: Без халә вокзал әтрафында нимсә хаммалы илә бербеременең сүзене аңламайадан (آڭلايه مدن) wакыт кичерийурыз [Кәрими, 1902, б. 61]; Биш-ун данә алманы вә йахуд тарелкалары (табаклары) hawада сикердеп hич бересене дөшермәдән (دوشورمه دن) мәhарәт күстәрийурлар [Кәрими, 1902, б. 79]; Бер мөддәт бунлар илә қонушмадан (قونوشمه دن) вә танышмадан (طانيشمه دن) килдек исә дә, узун бер тоннель кичдекдән соңра анасы безә бакып бер шәй сурды [Кәрими, 1902, б. 143]; Мәгарифле барышня илә гүзәл-гүзәл мөсахәбәтләр идеп вардығымыздан wақытың кичдеге тоелмадан (طويولمادن) да қалмыш, ақшам өсте сәгәт алты иде Ряжски вокзалына йитдек [Кәрими, 1908, б. 21] h.б.

Аерым очракларда *-мадан* формасы җөмләдәге төп эш-хәрәкәтнең үтәлү шарты турында сөйләгәндә дә кулланыла: Бу музәдәге китапларың кәсәрәт вә тәнәүвыгы хақында бер фикер әҗмале вирә белмәк ичүн бәгзеләренең исемләрене бурайа йазмадан (يازمه دن) кичәмийәҗәгем [Кәрими, 1902, б. 45]; Бу кәрамәтле шәйехе күрмәдән (كورمه دن) китмәк асла мөмкин дәгел [Кәрими, 1902, б. 114].

Госманлы төрек теле үзенчәлеге саналган *-мадан* кушымчалы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә генә очрыйлар. Башка язма чыганаклар өчен алар хас түгел. Бу әлеге хәл фигыльләрнең әдәби телдә гомумкулланылышка кереп китә алмавы белән аңлатыла. Нәтиҗә ясап әйткәндә, *-мадан* кушымчалы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби теле өчен хас булган функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*Исем фигыль.* Хәзерге татар тел белемендә исем фигыль исеме астында үзендә фигыль һәм исемнәргә хас үзенчәлекләрне берләштергән һәм процессны атап, аның исемен белдереп килгән затланышсыз фигыль формасы карала.

Фигыль формасы буларак исем фигыльләр семантик планда эш-хәрәкәт мәгънәсен белдерәләр. Морфологик яктан аларга фигыльләрнең гомуми грамматик категорияләре хас. Аерым алганда, исем фигыльләр үзләренә юклык һәм юнәлеш кушымчаларын алырга мөмкиннәр. Моннан тыш, сөйләмдә алар синтетик һәм аналитик юл белән эшнең үтәлү дәрәҗәсен, модаль мәгънәләрне белдереп килә алалар, кайбер ярдәмче фигыльләр белән бергә перифрастик конструкцияләрне төзүдә катнашалар.

Бүгенге көндә татар теле диалектларында исем фигыльнең биш формасы теркәлгән [Юсупов, 2004, с. 240–278]. Әдәби телдә аның *-у/-ү* кушымчасы ярдәмендә ясалган формасы норма буларак аерып чыгарыла [Татарская грамматика, 1997, с. 233–235; Тумашева, 1978, б. 158–160; Хисамова, 2006, б. 263–269].

Хәзерге татар әдәби телендә норма буларак кабул ителгән *-у* кушымчалы исем фигыльләрнең төрле дәрәҗәдә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби телендә дә кулланылуы күзәтелә. Шуның белән бергә бу чорга караган язма текстларның тел тукымасын иске татар әдәби теленең традицион үзенчәлекләреннән саналган *-мак* һәм госманлы төрек теле өчен хас булган *-ма, -маклык* формаларындагы исем фигыльләр дә тәшкил итә.

*-у* кушымчалы исем фигыльләр. *-у* кушымчалы исем фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтче язучыларыннан З. Бигиев һәм Р. Фәхретдиннең романнары өчен хас. Башка авторларда алар теркәлмәде. Мисаллардан күренгәнчә, әлеге исем фигыльләр фигыль нигезенә *-у/-ү* (-و-/ۋ) кушымчасы ялганып ясалалар: мәқтүлә булуы (مقتوله بولوى) [Бигиев, 1887, б. 6], килүе (كلوۋى) [Бигиев, 1887, б. 13], сөйләүләре (سويلۋلرى) [Бигиев, 1887, б. 31], сайлау (سايلاۋ) [Бигиев, 1887, б. 39], уқуы (اوقووى) [Бигиев, 1887, б. 40], зан қылулары (ظن قيلولرى) [Бигиев, 1887, б. 72], чығуы (چغوى) [Бигиев, 1887, б. 74], күрешүем (كوروشوم) [Бигиев, 1890, б. 18], хәреж итү (حرج ايتو) [Бигиев, 1890, б. 21], еғьлау (يغلاو) [Бигиев, 1890, б. 31], қайту (قايتو) [Бигиев, 1890, б. 62], ташулары (تاشولرى) [Фәхретдин, 1899, б. 14], йығлаулары (يغلاولرى), йуатулары (يواتولرى) [Фәхретдин, 1899, б. 14], қайтуы (قايتوى) [Фәхретдин, 1899, б. 34], сөйләшүе (سويلشووى) [Фәхретдин, 1903, б. 66], уқыту (اوقوتو) [Фәхретдин, 1903, б. 85] һ.б.

З. Бигиев *-у/-ү* кушымчалы исем фигыльләрне, автор сөйләмендә куллану белән бергә, персонажлар сөйләменә дә кертеп җибәрә:

«Унике сәғәтдә кидүене (كيدوونى) йақыйнан нәдән белдең?» – дийү сөаль қылдықда, хадим-швейцар бу тариқа җаwаб вирде: «Чөнки мәрхүмә илә бәрабәр килгән адәм номерәләрдән кидәркән: “Қач сәғәт?” – дийү бәндән сөаль қылды, бән, сәғәткә қарап: “Унике сәғәт”, – дийү җаwаб вирдем» [Бигиев, 1887, б. 6];

– Мондый эшләрдә еғлау (يغلاو) һич дә файда вә ярдәм қылмыйдыр – дийү, Ибраһим бөйлә сүзләрә дәвам итде: – ...Әгәр дә йахшы җаwаб хәзерләб барсаң, ... бер дә ғаебсез улып, бу эшдән хәлас булуың да (حلاص اولوونكده) мөмкиндер [Бигиев, 1890, б. 31].

3. Бигиевнең романнарында *-у* кушымчалы исем фигыльләрнең барлык килешләрдә дә һәм, нигездә, III зат тартым кушымчалары белән кулланылулары күзәтелә. Баш килештәге *-у* кушымчалы исем фигыльләргә язучы нинди дә булса эш-хәрәкәт яисә вакыйга турында сөйләгәндә мөрәҗәгать итә: ...мөсафирә Зөләйханың мәқтүлә булуы (مقتوله بولوى) сәкез сәгәт илә унике сәгәт мабәйнендә wақыйғ улдығыны аңладылар [Бигиев, 1887, б. 6–7]; Йарым сәгәт кичдекдән соңра секретарьнең уқуы (اوقووى) тәмам улды [Бигиев, 1887, б. 40]; Минем дә сәнең илә қалған вә ахырғы күрешүем (كوروشوم) бу кичә улсын... [Бигиев, 1890, б. 18]; Мондый эшләрдә йығлау (يغلاو) һич дә файда вә йәрдәм қылмыйдыр [Бигиев, 1890, б. 31] һ.б.

Текстларда баш килештәге *-у* кушымчалы исем фигыльләрнең исем сүзтезмәләр составында атрибутив позициядә кулланылу очраклары да күзәтелә: Сәгәт 7 гә чақлы магазинда ултырдым, соңра ивгә қайту (قايتو) нийәте илә магазиндан китдем, ... [Бигиев, 1887, б. 9–10]; Муса әфәнде: «Бик йахшы» – диб йирендән торып, кәғәз алу (آلو) мақсуды илә икенче бүлмәйә барыркән, ... [Бигиев, 1887, б. 16]. ... тәрәзәдән ташлаған wақытда сурәт әҗзаларының ике тәрәзә арасында дөшеб қалу (دوشب قالو) ихтималы бар [Бигиев, 1887, б. 42].

Иялек килешендә бу исем фигыльнең бары бер генә кулланылыш үрнәге теркәлде: Дамелла Ғабдулла хәзрәтләренең мәхкәмәйә килүенең (كلووننك) сәбәбе: мөселман присяжный заседательләрне һәм мөселман шаһидләрне қәсәм-ант қылдырмақ иде [Бигиев, 1887, б. 39].

Юнәлеш килешендәге *-у* кушымчалы исем фигыльләр текстларда, нигездә, башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдерәләр: ...җәмәғәт номер яныннан таралмайынча, ... тәфтишчеләрнең чығуына (چغوينه) мөнтазир булып торалар [Бигиев, 1887, б. 4]; Бу эшдә шаһид дәгел сез, бәлки тәфтишдә табылған нәрсәләр сезнең қатыйле Зөләйха улуыңыза (قاتل زليخا اولوڤنكزه) дәләләт қылалар [Бигиев, 1887, б. 20–21]; Господин Ғабденнәсырның ул кичдә ивдә булмаwына (ايوده بولماوينه) бер кәғәз-йазу дәләләт қыладыр [Бигиев, 1887, б. 44]; Қара, ниндәй йаwыз хатын икән, йанғын вә кешенең йанып үлүенә (اولووينه) мөтәшәккерән, хәмед әйтә [Бигиев, 1890, б. 24].

Аерым очракларда автор аларны башка эш-хәрәкәтнең вакыт ягыннан башлангыч ноктасын күрсәткәндә файдалана: Бу 12 нче номердә торуыма (طروۋمه) бер айдан зийадә улмас [Бигиев, 1887, б. 28];

Менә инде аның Қазандан кидүенә (كيدووينه) сәкез-туқыз ай булды, һаман қайтмыйдыр [Бигиев, 1890, б. 18].

Төшем килешендә *-у* кушымчалы исем фигыльләр башка эш-хәрәкәтнең туры объектын атап киләләр: Унике сәғәтдә кидүене (كيدوونى) йақыйнан нәдән белдең? [Бигиев, 1887, б. 6]; Ғазизем, бу үткән гәҗәдә господин Шубинның сезгә бундайын хезмәт илә килүене (كلوونى) қайын атаңыз Әхмәди абзый беләме? [Бигиев, 1887, б. 16]; Йағқубның мәқтүл булуыны (مقتول بولوونى) яңа ишедәмен вә бу хатынны беренче дәфға күрәмен вә ниндәләйен хатын улдығыны да белмимен [Бигиев, 1890, б. 34] һ.б.

Чыгыш килешендәге *-у* кушымчалы исем фигыльләрне автор башка эш-хәрәкәтнең кыек объекты буларак куллана: Җәмғ улмыш җәмәғәт номер эченә керергә нә қәдәр қәсд итделәр исә дә, номергә керүдән (كرودن) мәнғы қылындылар [Бигиев, 1887, б. 4]; Муса әфәнде вә башқа мөсафирлар Хәдичә туташның йарықдан қарауындан (قراوۋندن) хәбәрдар дәгелләр иде [Бигиев, 1887, б. 33]; Следователь хезмәтченең үлүендән (اولوندن) хәбәр алмадығы ичүн, ... [Бигиев, 1890, б. 54] һ.б.

Урын-вакыт килешендә *-у/-ү* кушымчалы исем фигыльләрне автор сирәк куллана: Бән Ғабденнәсыр әфәнденең номерендә күргән револьвер илә Зөләйханың мәқтүлә булуында (مقتوله بولوۋنده) шик йуқ [Бигиев, 1887, б. 59]; ...револьверны һәм кәғәзне Зөләйханың номерендән алып чығуда (آلوب چغوده) Ғабденнәсыр әфәндейә нә файда вар? [Бигиев, 1887, б. 73].

Әсәрләрдә *-у/-ү* кушымчалы исем фигыльләрнең *илә* (ايله), *берлән* (برلن), *соңра* (برلن) һәм *қәдәр* (قدر) бәйлекләре белән кулланылу очраклары да теркәлде. Әлеге конструкцияләрне автор башка эш-хәрәкәтнең үтәлү вакытын тасвирлаганда файдалана: Мәқтүл булған көн мәктүбнең йазылуы илә (يازولوى ايله) бер көндәдер [Бигиев, 1887, б. 8]; Ниғмәтулла әфәнде вә Ғабденнәсыр әфәнденең Әхмәди байға қаршы чығулары берлән (قارشو چغولرى برلن) Әхмәди бай бер дәқиқа кәчдекдән соңра ив эченә кереп, ... [Бигиев, 1887, б. 16]; Зөләйханың мәқтүлә булуындан соңра (مقتوله بولوۋندن صنكره) тәфтишдә табылған нәрсәләр Муса әфәнденең қатыйль идегенә дәляләт қылалыр, гәрчә Муса әфәнде қатыйль булмаса да [Бигиев, 1887, б. 28]; Менә бән сезнең килүеңезгә қәдәр (كلوونكزكه قدر) номерне дә арытмадым, җыймадым [Бигиев, 1887, б. 60].

Р. Фәхретдин әсәрләрендә *-у* кушымчалы исем фигыльләр, нигездә, баш һәм төшем килешләрендә кулланылалар. Башка

килешләрдә алар сирәк очрый. Югарыда әйтеп үтелгәнчә, баш килештәге *-у* кушымчалы исем фигыльләр нинди дә булса эш-хәрәкәтне яисә вакыйганы атап киләләр: Пароход хезмәтчеләренең ашыгып нәрсә ташулары (نرسه تاشولری), яңмур күрелгәндә ашлык уручыларның йөгерә-йөгерә көлтә җыймакларыны искә төшерә иде [Фәхретдин, 1899, б. 14]; Йәш балаларның көйсезләнеп йыглаулары (يغلاولری), ана вә караучыларының анларны йуатулары (يواتولری), йакында пароход, йыракда улган завод вә тимер йул арбасы даwышларына кушылып, гәҗәб рәвешдә һаwага күтәрелеп, таралмакда иде [Фәхретдин, 1899, б. 14]; Җәмал вә гүзәллеге йирендә, сөйләшүе (سويلشووی) ләззәтле, кәндесе дә гайәт дә җәзибәле улдыгындан, ... [Фәхретдин, 1903, б. 66]; Алай укыту (اوقوتو) динемезгә хилаф, сезнең ичүн тәмугга керер хәлем йук! [Фәхретдин, 1903, б. 85] һ.б.

Иялек килешендә әлеге исем фигыльләр исем сүзтезмәләр составында атрибутив функциядә кулланылалар: ...йәки гүзәл холыклы галимләр тарафындан йазылган роман вә хикәйәтләрне күп укуының (اوقوينڭ) файдасыдыр, диб зан иттем [Фәхретдин, 1899, б. 27]; Ләкин бунларың бөйлә хилафлыкда йөрүләренең (يورولرينك) сәбәбене беләсем килеп тәфтиш итдем һәм белдем [Фәхретдин, 1903, б. 87].

Юнәлеш килешендәге *-у* кушымчалы исем фигыльләр башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдерәләр: Бәңа йырак дәгел урында ике хатын сүзләшүенә (سوزلشوينه) колак салып гаҗәб итдем [Фәхретдин, 1899, б. 16]; Мәгәр дә Казандан китүемә (كيتومه) тәүлек улмады, мәзкүр кийемләрне кидем [Фәхретдин, 1899, б. 30–31]; Һәр нә кадәр куанмадым исә дә, Хәсән агайның иткыйкад вә фикере алмашуына (آلماشوينه) гәҗәб идеп, бер харика дийә хөкем итмәкдә идем [Фәхретдин, 1899, б. 48].

Төшем килешендә әлеге исем фигыльләр башка эш-хәрәкәтнең туры объектын атап киләләр: ...олуг агач савытлар илә кымыз эчүләремне (قمز ايچولرمنی) фикерләп, аwызымдан сулар ага иде [Фәхретдин, 1899, б. 8]; Нә кадар урынлардан кичеп агуыны (آغونی) вә нә кәдәр җанларны сугаруыны (سوغارونی), дөнйа зурлыгы пароход илә безне күтәреп агызып баруыны (آعزوب بارونی) фикерләп, Аллаһы Тәгаләнең сәнгәтләренә хәйран улып утырыр идем [Фәхретдин, 1899, б. 22]; Үгезләр йигеп, арбаларың көпчәкләрене (тәгәрмәч) сары май илә майлап, сырт өсләрендән йөрүләрене (يرولرنی) сөйләдеге wакытында, ... [Фәхретдин, 1903, б. 20]; Үзең начар булсаң да, баланың йахшы булуыны (بولونی) арзу идәсең! [Фәхретдин, 1903, б. 82] һ.б.

Чыгыш килешендәге *-у/-ү* кушымчалы исем фигыльләрне автор башка эш-хәрәкәтнең кыек объекты буларак куллана: Хәтта ки, Рәсүле әкрәм әфәндемез (Салиулла ғaләйhиссәлам) хәзрәтләренә ифтира идүдән (افتراء ایدودن) чирқанмай, ... [Фәхретдин, 1899, б. 44]; Бу дәфғада Хәсән ағайның ысулы җәдид бәхәсене чықaруындан (چقاروندن) қурқып, мөмкин қәдәр тиз китмәк ичүн тәдбирләр қыла идем [Фәхретдин, 1899, б. 45].

Урын-вакыт килешендә *-у/-ү* кушымчалы исем фигыльләрне автор сирәк куллана: Бақчадан чықуымызда (چقوبمزده) лимон вә әфлисун сатучыларға туқталдық; җөмләсе мөселманлар иде [Фәхретдин, 1899, б. 34]; Хөсәйен хәзрәтең хилафлық идүендә (خلافلق ایدونده) ғәҗәб эш йуқ иде [Фәхретдин, 1903, б. 87].

Р. Фәхретдин әсәрләрендә *-у* кушымчалы исем фигыльләрнең *илә* (ایله), *қәдәр* (قدر) һәм *ичүн* (ایچون) бәйлекләре белән аерым кулланылыш очраклары да теркәлде: Балаларны җыйып, шу йаңа уқыду илә (اوقودو ایله) уқыдырға керешде [Фәхретдин, 1903, б. 82]; Ханымлар истирахәт итмәк улдылар; бән дә анлар йоқлаб торуларына қәдәр (یوقلاب torولرینه قدر) дачаға варып килмәкче улып, арба йаллап китдем [Фәхретдин, 1899, б. 39]; Сезең эш бетде, килүеңез ичүн (کلووکز ایچون) рәхмәт, дип қайтарып йибәрдем [Фәхретдин, 1903, б. 86].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка, сөйләм теле өчен хас булган *-у* кушымчалы исем фигыльләр газета текстларында, дини-фәлсәфи текстларда һәм шигъри әсәрләрдә дә кулланылалар [Миннуллин, 2012, с. 211–212; Абдулхаков, 2007, с. 22; Юсупов, 2006, с. 130–131]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норма, норма вариантлылыгының бер күрсәткече булып торалар.

*-ыш* кушымчалы исем фигыльләр. Әлеге исем фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләре өчен хас түгел. Биредә аларның бары тик М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында ике һәм Ф. Кәриминең «Йаурупа сәяхәтнамәсе»ндә бер кулланылыш очрагы гына теркәлде: Әмма бер көлешендә (کلشنده) қып-қызыл дудақлары вә ақ энҗе дешләре менланың күзендән қачмады [Акъегет, 1886, б. 10]; Әмма килешендә (کلشنده) Хисаметдин менла бик ризықлы вә бәхтияр улды [Акъегет, 1886, б. 20]. ...иғанә парасы тупланмақда исә дә, эшең кидеше (کیدیشی) пәк явашдыр [Кәрими, 1902, б. 54].

*-ма* кушымчалы исем фигыльләр. Госманлы төрек теле үзенчәлеге саналаған *-ма* кушымчалы исем фигыльләр [Кононов, 1956, с. 455–460] XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә еш очрый. Мисаллардан күренгәнчә, алар *-ма/-мә* (-م/-ما/-مه) кушымчасы ярдәмендә ясалалар: хәбес иделмәсенә (جبس ایدولمسینه) [Акъегет, 1886, б. 15], қычқырышмайы (قچقروشمه یی) [Акъегет, 1886, б. 16], фәқир улмасыны (فقیر اولمه سنی) [Акъегет, 1886, б. 17], кәчмәсене (کچمه سنی) [Акъегет, 1886, б. 25], мәйдана килмәсе (میدانه کلمه سی) [Акъегет, 1886, б. 29], ачыйғланмасы (آچیغلانمسی) [Акъегет, 1886, б. 54], тәфтиш улмасыны (تفتیش اولماسنی) [Бигиев, 1890, б. 34], чықмасыны (چقماسنی) [Бигиев, 1890, б. 53], күчерелмәсене (کوچرلمسنی) [Бигиев, 1890, б. 56], дәфен қылынмасыны (دفن قلنماسنی) [Бигиев, 1890, б. 57], вөжүдә килмәсе (وجوده کلمه سی) [Бигиев, 1908, б. 44], истила улынмамасы (استیلا اولنماماسی) [Бигиев, 1908, б. 48], күчеп килмәсе (کوچوب کلمه سی) [Бигиев, 1908, б. 98], хәбәрдар улмамалары (خبردار اولمامه لری) [Кәрими, 1902, б. 10], тәрҗемә улынмалары (ترجمه اولنمه لری) [Кәрими, 1902, б. 22], башламалары (باشلامه لری) [Кәрими, 1902, б. 52], ғизмәсе (کزمسی) [Кәрими, 1902, б. 120]. тәмиз тотылмасы (تمیز طوتولمسی) [Кәрими, 1902, б. 125], киредә қалмасы (کیروده قالمسی) [Кәрими, 1908, б. 5], сәвқ итмәсе (سوق ایتمسی) [Кәрими, 1908, б. 72], шапырданмасы (شاپردانمه سی) [Кәрими, 1908, б. 89], ғариб күренмәсе (غریب کورینمه سی) [Кәрими, 1908, б. 110], сарыф итмәсе (صرف ایتمه سی), хәзерләнмәсе (حاضرلنمه سی) [Фәхретдин, 1903, б. 13], иртихал итмәсе (ارتحال ایتمه سی) [Фәхретдин, 1903, б. 43], дөнйайа килмәсе (دنیایه کلمسی) [Фәхретдин, 1903, б. 92], ниқахланмасы (نکاحلنمه سی), бозышмасы (بوزشماسی) [Фәхретдин, 1903, б. 105] һ.б.

М. Акьегетнең «Хисаметдин менла» романында аларның баш, юнәлеш һәм төшем килешләрендә кулланылу очраклары теркәлде. Язучы аларны автор сөйләмендә куллану белән бергә, персонажлар сөйләменә дә кертеп җибәрә:

...

– Бәли, туғры хәбәр, – җаwаб вирде Хисаметдин менла.

– Бәлки туғры, әмма хәбес иделмәсенә (جبس ایدولمسینه) сез сәбәбҗе улдығыңыза без һич инанмыйуруз [Акъегет, 1886, б. 15];

...Бән исә ислам қардәшемнең фәқир улмасыны (فقیر اولمه سنی) һич эстәмәзмен. Күрәсез, хәзрәте рәсүл кәндесе дә кешедән сормақны сәвмәгән, – дийеп алды Хисаметдин менла [Акъегет, 1886, б. 17].

*-ма* кушымчалы исем фигыльләрне баш килештә язучы тартым кушымчалары белән генә куллана. Бу очракта алар аерым бер зат та-

рафыннан башкарылган эш-хәрәкәтне яисә аның белән бәйле вакыйганы атап киләләр: Менланың шәһәрә чуқ килмәсе (كلمه سى) диккәтсез қалмайып, ... [Акъегет, 1886, б. 20]; Иғтиқад вә әфкәре мөштәрәк уланлар арасында мөхкәм дустлық мәйдана килмәсе (ميدانه كلمه سى) бәдиһидер [Акъегет, 1886, б. 29]; Сүз сүздән соңра байның ачыйғланмасы (آچيغلانمسى) мөшахәдә улыныр иде [Акъегет, 1886, б. 54] һ.б.

Әсәрдә юнәлеш килешендәге *-ма* кушымчалы исем фигыльләрнең тартым кушымчалары белән бергә һәм алардан башка кулланылған очраклары теркәлде. Тартым кушымчаларыннан башка әлеге исем фигыльләрне автор түбәндәге рәвештә файдалана:

1) *башлау* фигыле белән бергә *-а* кушымчалы хәл фигыльләр урынында: Мәзкүр җәридәйе ачып уқымайа башлады (اوقميه باشلادى), ... [Акъегет, 1886, б. 5]; Уқымайы сәвмәк лязем дийү фикерләнә-фикерләнә Хисаметдин менла гәнә одасында ғизмәйә башлады (كزميه باشلادى) [Акъегет, 1886, б. 7]; Руслар ғилме механика, ғилме техника үгрәнмәйә башладылар (اوكرنميه باشلاديلر) [Акъегет, 1886, б. 31];

2) күчемле фигыльләр белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең кыек объектын күрсәтү өчен инфинитивның *-ырға* формасы урынында: Бер хаста, хәлсез күрсәк, йәрдәм бирмәйә (ياردم برميه) ... морад идәрез [Акъегет, 1886, б. 5]; Вә бунлардан мисал алып, үзе дә милләт файдасына ғайрәт вә сәғый итмәйә (غيرت و سعى ايتميه) қарар вирде [Акъегет, 1886, б. 30]; Бөйлә инсанларың һичбер файда қылмайа (فائده قلميه) зиһенләре ирешмәз [Акъегет, 1886, б. 32];

3) хәрәкәт фигыльләре белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең башкарылу максатын күрсәткәндә инфинитивның *-ырға/-ергә* формасы урынында: ...хезмәтче қадын сахибәсене уйғатмайа (اويغاتميه) китде [Акъегет, 1886, б. 8]; Төрле-төрле аwылдағы хәбәрләрдән менланың ғашыйқ җаны рәхәтсезләнеп, дәрхәл кич йоқламайып шәһәрә мәғшуқасыны эзләмәйә (ازلميه) йулланды [Акъегет, 1886, б. 64].

Тартым белән төрләнгән *-ма* кушымчалы исем фигыльләр юнәлеш килешендә башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдерү өчен кулланылалар: Зира беренче: мәктүбенә җаwабы Хәнифә ханым ихсан бойурмыш, икенче: менланың ғашыйқ улмасына (عاشق اولمسنه) да инанмыш, ... [Акъегет, 1886, б. 26].

Төшем килешендәге *-ма* кушымчалы исем фигыльләрне автор башка эш-хәрәкәтнең туры объекты буларак файдалана: Ғали бай үзе дә Хисаметдин менланың мәғлүб улмасыны (مغلوب اولمسنى) истийур иде, ... [Акъегет, 1886, б. 14]; Бу қычқырышмайы (قچقروشمه يى) ишедеп,

зийәфәтдә булынанларың бәғзеләре чәйләрене онытып, Бикбулат менланың шәкертләрендән хәйран қалдылар [Акъегет, 1886, б. 16]; Қарынына итағәтле ғаwам кеше уруҗ wақытында ничек көннең кәчмәсене (کچمه سنی) көтәдер, шөйлә менламыз да көннең тиз кәчмәсене (کچمه سنی) эстәр иде [Акъегет, 1886, б. 25] һ.б.

Югарыда санап кителгәннәрдән тыш, әсәрдә *-ма* кушымчалы исем фигыльләрнең *илә* (ایله) бәйлеге белән кулланылу очраклары да теркәлде: Әрсезлек вә кискенлек илә һәр көн берәр капик тапсаң да, заман кичмәсе илә (کچمه سیله) баймамақ мөхәлдер [Акъегет, 1886, б. 33–34]; Биң йыллара бақмаңыз, бу wақытдан зыйаланмаға таләбемез уйғанса, заман кичмәсе илә (کچمه سیله) без дә мәғлүматлы улырмыз... [Акъегет, 1886, б. 46].

З. Бигиев әсәрләрендә *-ма* кушымчалы исем фигыльләр баш, төшем, юнәлеш һәм чыгыш килешләрендә теркәлде. Баш килештә язучы аларны тартым кушымчалары белән генә куллана. Бу очракта исем фигыльләр аерым бер зат тарафыннан башкарылган эшхәрәкәтне яисә аның белән бәйле вакыйганы атап киләләр: Оренбург Духовный собрания қазыйлары җәһәтенә кермәк ичүн гимназиянең дүрт классы програмындан йәки уездный, я городской, я учительский мәктәбләрнең програмындан тәхсыйль улынан фәнләрдән имтихан бирмәләре (امتحان برملری) ляземдер [Бигиев, 1890, б. 13]. Әгәр дә сән шулай җығлаб, следовательнең сүзләренә җаwаб хәзерләмәйенчә, следователь хозурына барсаң, һич дә миһләт вирмәйенчә, следователь сәне хәбесханәйә йулламасы (یوللامسی) мөтәйәққыйн вә бәдиһидер [Бигиев, 1890, б. 31]; ...йағмачылық илә ғөмер идәр төрекмәнләрең вөҗүдә килмәсе (وجوده کلمه سی) Русийәдә Дон казакларының вөҗүдә килмәсе кебидер [Бигиев, 1908, б. 44]; ...иң соң заманлара қәдәр Төркестаның, йахуд ғомумән Урта Асийәнең Йаурупа дәүләтләре тарафындан истила улынмамасы (استیلا اولنماماسی) бер қәдәр ғәрибдер... [Бигиев, 1908, б. 48].

Автор юнәлеш килешендәге *-ма* кушымчалы исем фигыльләрне тартым кушымчаларыннан башқа түбәндәге рәвештә файдалана:

1) *башла-* фигыле белән бергә *-а* кушымчалы хәл фигыльләр урынында: Бер дәқиқа кәчкәч, старшина, ашықмайынча, борнысындағы күз көзгесене төзәтеп, присяжный заседательләрнең иттифақы нә идегене уқымайа башлады (اوقومیه باشلادی) [Бигиев, 1887, б. 46]; Шимди йәшләремез Муса әфәнде илә Хәдичә туташ, морадларына тәмамән ирешеп, бәхтийар улып, зәwең вә сафа чикмәйә башладылар

(ذوق و صفا چکمیه باشلادیلر) [Бигиев, 1887, б. 77]; Хәмзә бай мөсафирләрдән соңра ярым сәгәт эчендә җатып йоқламайа башлады (یوقلامیه باشلادی) [Бигиев, 1890, б. 11]; Исмәгил Самани соңында Саманиләрең шәүкәте инмәйә башлады (اینمیه باشلادی) [Бигиев, 1908, б. 4] һ.б.;

2) күчемле фигыльләр белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең кыек объектын күрсәтү өчен инфинитивның *-ырга* формасы урынында: ...Ләкин бу хәлемдә сәфәр қылмайа (سفر قیلمایه) табиблар мәслихәт вә рөхсәт вирмиләр [Бигиев, 1890, б. 17]; Гизлеҗә бала туғдырмайа (توغدرمیه) эстәйән хатынлара йәрдәм қыламын [Бигиев, 1890, б. 35]; Чынгызларың хезмәтендә улан уйгур төрекләре иске хәлләренә гәүдәт итмәйә (عودت ایتمیه) гайрәт қыла башладылар [Бигиев, 1908, б. 8]; Чыңгыз шәррендән имин булмақ ичүн, төрекмәнләр һиҗрәт итмәйә (هجرت ایتمیه) мәҗбүр улып, ... [Бигиев, 1908, б. 43] һ.б.;

3) хәрәкәт фигыльләре белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең башкарылу максатын күрсәткәндә инфинитивның *-ырга* формасы урынында: Әқрабы вә қарендәшләре Габделгафурны мәдрәсәйә озатмайа (اوزاتمیه) килмешләр [Бигиев, 1890, б. 5]; Әшйә вә әсбабларны номерә-мөсафирханәдә қалдырып, кәнделәре Хәмзә байга күрешмәйә (کوروشمیه) килмешләр [Бигиев, 1890, б. 8–9]; Регистаны тамаша итмәйә (تماشا ایتمیه) китдем [Бигиев, 1908, б. 75] һ.б.

Төшем килешендәге *-ма* кушымчалы исем фигыльләрне автор башка эш-хәрәкәтнең туры объекты буларак файдалана: ...қарчықның өйендән тәфтиш улмасыны (تفتیش اولماسنی) риҗа қылды [Бигиев, 1890, б. 34]; ...Мәмәтнең номерәдән, Габделгафур йанындан чықмасыны (چقماسنی) таләб иткәч, ... [Бигиев, 1890, б. 53]; ...Маһруйның үлекләр өчен улан бүлмәйә күчерелмәсене (کوچرلمسنی) әмер бойырды [Бигиев, 1890, б. 56].

Әсәрләрдә чыгыш килешендәге *-ма* кушымчалы исем фигыльләр тартым кушымчаларыннан башка гына кулланыла: ...бөйлә қабер кеби бүлмәйә мәхбүс хәле хисабсыз вә бәйан хариҗендә ағыр wақыйга улып, мәүлә мөтәгали сабыр вә тәхәммел бирсен димәдән (دیمدن) гайре сүз йуқдыр [Бигиев, 1890, б. 23]; Һәм, wақыйган, мөфәттин Ибраһимның әйтдеге кеби, балайы «тәмам» қылмадан (»تمام« قیلمه دن) мордар қарчықга ағыр мәшәқәт килмәде [Бигиев, 1890, б. 33]; ...хиқәйәмезең дәвамы wақытында өйдә Маһруйның баласы Фәридәйе бақмадан (باقمه دن) гайре хезмәте йуқ иде [Бигиев, 1890, б. 59].

Урын-вакыт килешендә әлеге исем фигыльләрнең бары бер генә кулланылыш очрагы теркәлде: ...қуәтле йилләрдә Волга ташымаларында (طاشمه لارنده) шәһәр тәмамән батар иде [Бигиев, 1908, б. 32].

Югарыда санап кителгәннәрдән тыш, әсәрләрдә *-ма* кушымчалы исем фигыльләрнең *илә* (ايله) бәйлеге белән кулланылу очраклары да теркәлде. Автор *-ма илә* конструкциясенә башка эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын күрсәткәндә мөрәҗәгать итә: Бу хәбәрнең хақыйқатене белә алмайынча, Җиһангир, Қазанға тәвәҗжеһләнеп, лязем қәдәр мөддәтнең кичмәсе илә (کچمه سيله), Қазанға килеп йитде [Бигиев, 1890, б. 37]; Ун-унбиш дәқиқа wақытның мөрүр идмәсе илә (مرور ايدمه سيله) Маһруй, қуәтене җәмғ идеп, ... [Бигиев, 1890, б. 58].

Р. Фәхретдин әсәрләрендә *-ма* кушымчалы исем фигыльләр нигездә баш, юнәлеш һәм төшем килешләрендә очрый. Баш килештә язучы аларны тартым кушымчалары белән генә куллана. Бу очракта әлеге исем фигыльләр аерым бер зат тарафыннан башкарылган эш-хәрәкәтне яисә аның белән бәйле вакыйганы атап киләләр: Шуның ичүн Ғаббас мелланың бөйлә рәвешдә зиһен сарыф итмәсе (صرف ايتمه سى) вә бүйүк бер мөхарәбәйә кидәчәк сарғаскәр мәнзилендә хәзерләнмәсе (حاضرلنمه سى) урынсыз дәгел иде [Фәхретдин, 1903, б. 13]; Wақыйға Ғаббас мелланың бөйлә бер wақытда иртихал итмәсе (ارتحال ايتمه سى), дәгел қарйа әһеленә, бәлки бөтен милләт ичүн олуғ бер қайғы идеге шөбһәсездер [Фәхретдин, 1903, б. 43]; Хикмәт хаҗинең Хәмидәне ниқахланмасы (نكاحلنمه سى) йәһүди фикере илә улдығы кеби, соңра бозышмасы (بوزشماسى) да бунның морады үзәренә улмыш иде [Фәхретдин, 1903, б. 105].

Автор юнәлеш килешендәге *-ма* кушымчалы исем фигыльләрне тартым кушымчаларыннан башка түбәндәге рәвештә файдалана:

1) *башла-* фигыле белән бергә *-а* кушымчалы хәл фигыльләр урынында: Ошбу хатының ғайрәт вә һиммәте сайәсендә Ғаббас мелла да кәндесенә йабышмыш улан фәна ғәдәтләрене берәм-берәм өстендән төшермәйә (توشرميه) вә табиғый истиғдадыны хәрәкәтләндермәйә башлады (حركتلندرميه باشلادى) [Фәхретдин, 1903, б. 5]; ...һәм дә бүйүк бер ихлас вә хирыс илә уқымайа башлады (اوقوميه باشلادى) [Фәхретдин, 1903, б. 6]; ...бу йаңа килмеш хатын әтрафыны ихата идеп сорашмайа башладылар (صوراشميه باشلاديلر) [Фәхретдин, 1903, б. 71];

2) күчемле фигыльләр белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең кыек объектын күрсәтү өчен инфинитивның *-ырға* формасы урынында: Ләкин мәзкүр фикерене тәмам йиренә китермәйә (يرينه كتورميه) Ғаббас мелла муафыйқ улмады, ... [Фәхретдин, 1903, б. 7]; Йосыф бабай намаз уқымайа (ناماز اوقوميه) қартайдығы wақытында мәсҗедә йөреп, кешеләрдән күреп кенә өйрәнмеш иде [Фәхретдин,

1903, б. 47]; Өч һәфтә микдары салынмыш урынында ятдығындан сон, култық тайағына тайанып хастаханә эчендә йөрмәйә (یورمیه) рөхсәт улынды [Фәхретдин, 1903, б. 68];

3) аерым очракларда хәрәкәт фигыльләре белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең башкарылу максатын ачыклау өчен инфинитивның *-ырга* формасы урынында: ...Әсма ханым атасы Ғаббас мелла илә мөләқат итдегендән соң, тәрбийәханәйә қайтмайа (قایتمیه) чықтығында айақларындан мәхрүм қалан бер хатын деләнчейә туғры килеп, садақа виреп китмеш иде [Фәхретдин, 1903, б. 123].

Чыганакларда тартым белән төрләнгән *-ма* кушымчалы исем фигыльләр юнәлеш килешендә башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдереп киләләр: Wақыйған бу ғәдәтләре бунлар ичүн қымыз эчмәк вә сәяхәт итмәкдән күп мәртәбә артық бәдәнләренең сәламәтлекләренә вә күңелләренең шад улмасына (شاد اولماسنه) сәбәб улыр иде [Фәхретдин, 1903, б. 9]; Һич бер ғөнаһы йуқ икән, Ғаббас мелланың ғөрбәт ихтийар итмәсенә (اختیار ایتمه سنه) сәбәб улдым [Фәхретдин, 1903, б. 105].

Төшем килешендәге *-ма* кушымчалы исем фигыльләрне автор башка эш-хәрәкәтнең туры объекты буларак файдалана: Шу көнләрдә гәзитәләрең берендә бер қысқа фикерле кемсә тарафындан ғомум ислам хақында күнелсез бер ифтира йазылдығында, бер қадар хамийәтле кемсәләр килеп, өч-биш сәтыр илә улсын, җаwаб йазмасыны (جواب یازمه سنی) рижа итдекләрендә, төрле-төрле буш бәханәләр илә рәд җаwабы вирмеш иде [Фәхретдин, 1903, б. 52]; Ләкин безем шәкердемез бу балдағың тарихыны әүwәлдән гүзәл белдегендән Әсмада тормасыны (طورماسنی) истәр иде [Фәхретдин, 1903, б. 56].

Чыганакларда әлеге исем фигыльләрнең чыгыш һәм урын-вакыт килешләрендә бары бер генә кулланылыш очрагы теркәлде: ...вә ниһайәт фахишәләр илә төн кичермәсендән (تون کیچرمه سندن) гел мөридләрең бөйлә бозық улачақларыны хөкем әйләмәк дөрест улыр иде [Фәхретдин, 1903, б. 39]; Буның фикеренә күрә хатынның күп вә аз улмасында бер айырма улмай, ғаилә вә әдәб җәһәтенчә, хатын күп улмасында (کوب اولمه سنده) һәм қосурлық күрмәз иде [Фәхретдин, 1903, б. 18].

Ф. Кәрими сәяхәтнамәләрендә *-ма* кушымчалы исем фигыльләр барлык килешләрдә дә һәм нигездә тартым кушымчалары белән кулланылалар. Баш килештә алар аерым бер зат тарафыннан башкарылган эш-хәрәкәтне яисә аның белән бәйле вақыйғаны атап киләләр: ...буның йаздықларындан хәбәрдар улмамалары (خبردار اولمامه لری), бәнҗә, шайан тәәссефдер [Кәрими, 1902, б. 10]; Араларындан йул булып гизмәсе

(کزمسی) гүч [Кәрими, 1902, б. 120]; Милләтемезең һәр җәһәт илә киредә қалмасы (کیروده قالمسی) указлы меллаларымыз азлығындан дәгел, бәлки указсыз меллаларымызың азлығындан иде [Кәрими, 1908, б. 5]; ...дигәр тарафдан да Қара диңгез далғаларының мөтәмәдийә сахилә чарпып шапырданмасы (شاپردانمه سی) пәк гүзәл вә шағыйранә манзара тәшкил итмәкдә иде [Кәрими, 1908, б. 89] һ.б.

Сәяхәтнамәләр өчен баш килештәге *-ма* кушымчалы исем фигыльләрнең исем сүзтезмәләр составында башка сүзне ачыклап, атрибутив позициядә кулланылулары да хас: ...сүзе кәндесенең ғарәбҗә үгрәтмәсе (اوگرتمسی) хосусына китерәрәк, бунын нә тариқҗа улдығыны сөаль итдем [Кәрими, 1902, б. 115]; Қара диңгез буйында вә хосусан Феодосия вә Қафа тарафларында җәнәвизлеләрдән қалма (قالمه) биналар, қальгалар, қалалар кеби бер тақым иске әсәрләр хәзер дә вардыр [Кәрими, 1908, б. 41]; ...тимер йул қазасындан қуртылмалары (قورتلمه لری) йәдкәренә ғайәт гүзәл архитектура илә йапылмыш бер мәрмәр чишмә вардыр [Кәрими, 1908, б. 59].

Иялек килешендә әлеге исем фигыльләр исем сүзтезмәләр составында башка сүзләрне ачыклап киләләр: ...вә бунлар арасына насыл улса да ғөлүм, мәғәриф, һөнәр вә сәнәғәт әдхаль итмәнең (ادخال ایتمه نڭ) чарасыны дөшенийурлар [Кәрими, 1902, б. 24]; Әвәт, утыз дәресдә ғарәбҗә сөйләшмәгә, йазмаға вә уқып аңламаға үгрәтмәнең (اوکرتمه نڭ) йулыны кәшеф итдем [Кәрими, 1902, б. 115–116]; Кәндесенең вә ғомумийәтлә Қырым татарларының Төркийәйә һиҗрәт итмәләренең (هجرت ایتمه لرینك) сәбәбләрене сурдым [Кәрими, 1908, б. 47]; Йәрдәм вә мөғәwәнәтләре тәртибле вә файдалы сурәтдә иҗра итмәнең (اجرا ایتمه نك) лөзүмләре аңлашылды [Кәрими, 1908, б. 85] һ.б.

Чыганакларда *-ма* кушымчалы исем фигыльләр юнәлеш килешендә башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдереп киләләр: Пашпорт қайд итдермәк ичүн консулханәйә кәндемезең вармамыза (وارمامزه) асла ихтыяҗ улмайып, ... [Кәрими, 1902, б. 67–68]; ...мәдәнийәтдән мәхрүм улмаларына (محروم اولمالرینه) сәбәб дине ислам дәгелдер [Кәрими, 1902, б. 187]; ...милләтемез арасына ғилем вә мәғрифәт таралып, фикер ачылмасына (فکر آچیلمه سینه) пәк чуқ хезмәт итде [Кәрими, 1908, б. 3]; ...берчуқ фөқра әүлядының адәм улмасына (آدم اولمه سینه) вә эшә кермәсенә (ایشه کیرمه سینه) сәбәб улмақдадыр [Кәрими, 1908, б. 9] һ.б.

Төшем килешендәге *-ма* кушымчалы исем фигыльләрне автор башка эш-хәрәкәтнең туры объекты буларак файдалана: Нимсәҗә бел-

мийурыз, франсызҗа сөйләмәңезе (سويلمڭزى) риҗа идәрез, дидек исә дә, французҗа сөйләмәде [Кәрими, 1902, б. 61]; Дөнйада wакытда дөрле фәналыкда булынан адәмләрең дөрлеҗә ғазаб улынмаларыны (عذاب اولنمه لرينى) вә атәшдә йанмаларыны (آتشده يانمه لرينى) күстәрийурлар [Кәрими, 1902, б. 136]; Бән вокзала чыкып керәчәгем, әгәр сез чыкмайаҗак исәңез, лүтфән, бәнем әшйамы да бакмаңызы (باقمه ڭزى) риҗа идәрем [Кәрими, 1908, б. 15].

Чыгыш килешендәге *-ма* кушымчалы исем фигыльләрне автор башка эш-хәрәкәтнең кыек объекты буларак куллана: Кәндесе ғөлүме динийәдә гүзәл бер мәғлүмат сахибе улып, русҗа конушмаға маһир идеге, эксәр сүзләре русҗа сөйләмәсендән (سويلامه سندن) мәғлүм иде [Кәрими, 1902, б. 29]; ...фәлән вә фәлән дийә бер фәндән беркач шәрехләр вә хашийәләр саймадан (صايمه دن) башка бер чарам йук иде [Кәрими, 1902, б. 95]; Башкаларының дәхи шөйлә мөтәләзиз улдыклары мөтәмәдденан әл чарпып, бер бере аркасындан өчәр кат сәхнәйә дәғвәт итмәләрендән (دعوت ايتمه لرندن) аңлашылыйур иде [Кәрими, 1902, б. 124].

Урын-вакыт килешендә *-ма* кушымчалы исем фигыльләрне автор сирәк куллана: Затән, дөнйаның сафасы да шу инсанларың дөрле диндә, дөрле мәзһәбдә, дөрле мәсләкдә вә дөрле калып вә кыйәфәтдә вә фикерләренең һәм мөхтәлиф улмасындадыр (مختلف اولماسنده در) [Кәрими, 1908, б. 25]; ...бүгенге көндә кәнделәре дә сачларыны вә мыйыкларың дәхи ағыза кереп тормасында (كيروب طورمه سنده) сиххәтә зарар улдығыны кәшеф идеп, мыйыкларыны кисмәгә башладылар [Кәрими, 1908, б. 111].

Сәяхәтнамәләрдә *-ма* кушымчалы исем фигыльләрнең *ичүн* (ايچون) һәм *кәдәр* (قدر) бәйлекләре белән кулланылу очраклары да теркәлде: ...пәк чук wакытлар шу хезмәте мөкаддәсәңезә дәwам илә кәсеб шәрәф итмәңез ичүн (شرف ايتمڭز ايچون) җәнабе хака доға вә нийаз идәрез [Кәрими, 1908, б. 80]; Бу мәктәбең бөйлә гүзәл вә эхалийә файдалы сурәтдә дәвам итмәсе ичүн (دوام ايتمسى ايچون) фәхри назыйры улан Әмир Хәсән әфәнде Бакиров ... чук ғайрәт күстәрийурды вә халә дә күстәрмәкдә имеш [Кәрими, 1908, б. 112]; ...бунның нәселе улан ханлар Кырымың Русия тарафына кичмәсенә кәдәр (كچمه سينه قدر) дәwам вә хөкүмәт итмешләрдер [Кәрими, 1908, б. 41].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка, госманлы төрек теле өчен хас булган *-ма* кушымчалы исем фигыльләр шигъри әсәрләрдә генә кулланылалар [Юсупов, 2006, с. 130]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар бу чорда иске та-

тар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алмыйлар һәм XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби теле өчен хас булган функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*-мақ* кушымчалы исем фигыльләр. *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр иске татар әдәби теленең борынгыдан килгән традицион үзенчәлекләреннән саналалар. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында аларның кулланылыш даирәсе тагын да киңәя. Мисаллардан күренгәнчә, әлеге исем фигыльләр *-мақ/-мәк* (-مق/-مك) кушымчасы ярдәмендә ясалалар: дошман күрмәк (دشمان كورمك), [Акъегет, 1886, б. 5], алмақ (آلمق) [Акъегет, 1886, б. 10], уғрашмақ (اوغراشمق) [Акъегет, 1886, б. 20], көтмәк (كوتمك) [Акъегет, 1886, б. 25], йазу йазмақ (يازو يازمق) [Бигиев, 1887, б. 7], йәмәк вә эчмәк (يمك و اچمك) [Бигиев, 1890, б. 5], нәфәс алмақ (نفس آلمق) [Бигиев, 1890, б. 58], зийарәт итмәк (زيارت ايتمك) [Бигиев, 1908, б. 1], васыл итмәк (وصل ايتمك) [Бигиев, 1908, б. 14], зыяфәт вирмәк (ضيافت ويرمك) [Бигиев, 1908, б. 70], гизмәк (كزمك) [Кәрими, 1902, б. 7], уғрашмақ (اوغراشمق) [Кәрими, 1902, б. 36], мәғлүмат алмақ (معلومات آلمق) [Кәрими, 1902, б. 56], тәшәккер итмәк (تشكر ايتمك) [Кәрими, 1908, б. 3], күрешеп қайтмақ (كوريشوب قايتمق) [Кәрими, 1908, б. 4], талақ итмәк (طلاق ايتمك), малик улмақ (مالك اولمق) [Кәрими, 1908, б. 22], күрмәк (كورمك), белмәк (بيلمك), гизмәк (كزمك) [Кәрими, 1908, б. 40], читкә чықмақ (چيتكا چقمق) [Фәхретдин, 1899, б. 6], йығламақ (يغلامق) [Фәхретдин, 1899, б. 7], шөбһәләнмәк (شبه لنمك) [Фәхретдин, 1899, б. 9], фикер итмәк (فكر ايتمك), хезмәт итмәк (خدمت ايتمك) [Фәхретдин, 1899, б. 12], қалдырмақ (قالدرمق) [Фәхретдин, 1903, б. 26], дәлил сурмақ (دليل صورمق) [Фәхретдин, 1903, б. 62] һ.б.

М. Акьегет *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне, автор сөйләмендә куллану белән бергә, персонажлар сөйләменә дә кертеп җибәрә:

...

– Китабда бойырмыш ки, соранмақ (صورانمق) фәқирлеккә сәбәбдер, – җаwаб вирде Хисаметдин менла.

...

– Қанғы китабда димеш ки, соранмақ (صورانمق) фәқирлек ки?

...

– Хәзрәте рәсүле салиулла ғаләйхиссәлләм хәзрәтләре димешләрдер ки, кәндесе ичүн бер кемсә сурмақдан (صورمقدن) бер қапы ачса, Аллаһы хәзрәтләре ачар аңа фәқирлекдән йитмеш қапы. Бән исә ислам қардәшемнең фәқир улмасыны һич эстәмәзмен. Күрәсез, хәзрәте

рәсүл кәндесе дә кешедән сурмақны (صورماقنى) сәвмәгән, – дийеп алды Хисаметдин менла [Акъегет, 1886, б. 16–17];

...

– Йегерме-утыз манит ақча эш башламақ (ايش باشلامق) ичүн бән дә вирер идем, – диде Әбүзәр бәк.

– Йуқ, йуқ, Әбүзәр бәкдән ақча алма. Кеше ақчасы илә эш башламақ (ايش باشلامق) йегетлек дәгел, һәм эш файдасыз булып кидәр, чүнкә ақчаның қадерене белмәзсең, – диде Хисаметдин менла [Акъегет, 1886, б. 33].

«Хисаметдин менла» романында *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрнең тартым кушымчалары белән һәм алардан башка баш, юнәлеш, төшем һәм чыгыш килешләрендә кулланылулары күзәтелә. Баш килештә әлеге исем фигыльләр аерым бер зат тарафыннан башкарылган эш-хәрәкәтне яисә аның белән бәйле вакыйганы атап киләләр: Хәсәдлек кеби бүйүк бәлайә мөбтәлә улан адәме Хисаметдин менла дәгел дошман күрмәк (دشمان كورمك), билғакес айар иде [Акъегет, 1886, б. 5]; Ахыр Хәнифә туташа да менла илә уғрашмақ (اوغراشمق) дәхи хуш иде, ... [Акъегет, 1886, б. 20]; Җаwаб улачақ wақытны, йәғни икенче көн иртә wақытны көтмәк (كوتمك) менламыза бик мөшкел күренде [Акъегет, 1886, б. 25]; Хәнифәнең ғаиб улып менла илә күрешмәге (كوروشمكى) абыстайы зийадәсе илә рәхәтсезләде [Акъегет, 1886, б. 68].

Автор баш килештәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне, еш кына, исем сүзтезмәләр составында атрибутив позициядә куллана: Хисаметдин менла шәһәрә килеп аwылдашы Мохтарны диләнмәк (ديلنمك) эшендә күреп... [Акъегет, 1886, б. 30]; Анҗақ Хәнифә туташ үзене Сибғатулла әфәндегә вирмәк (ويرمك) морадларыны аңлаб йинә зийадә мөкәтдәрә улды [Акъегет, 1886, б. 36]; Бундан бөйлә мәзкүр қәдәр вә қайғысыны менла Хисаметдингә белдермәк (بلدرمك) форсатыны Хәнифә туташ күзләр иде [Акъегет, 1886, б. 36].

Шуның белән бергә әлеге исем фигыльләр предикатив позициядә дә теркәлделәр: Бунлар белмәзләр ки, бәхәсдән морад шәйне, йахшырақ муазна идеп фәһемләмәкдер (فهملمك در), ләкин бәхәсдән морад қычқырышмақ (قچقرشماق) дәгел [Акъегет, 1886, б. 18].

Әсәрдә баш килештәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр инфинитивның *-ырға* формасын да алыштырып киләләр. Бу түбәндәге очракларда күзәтелә:

1) *эстә-* фигыле белән бергә кулланылганда: Йәш әфәнде чуқдан бу кеби кеше илә таныш улмақ эстийур иде (نانوش اولمق استيور ايدى)

[Акъегет, 1886, б. 8]; Менланың кердегене белеп вә бер күрмәк эстәп (كورمك استاب) Хәнифә туташ эшене ķуйып, ... [Акъегет, 1886, б. 10]; Бу мәктүбемдә бән сәңа бер йәни wаķыйға белдермәк эстәмеш идем (بلدلرمك استمش ايدوم) [Акъегет, 1886, б. 39];

2) *мөмкин* (ممكن), *мөхәл* (محال), *лязем* (لازم), *кирәк* (كراك) модаль сүзләре белән бергә килгәндә: Чүнкә ғәwәм йахшы белер ки, Ғали байны тәғзим итсәң, тупрағыны вә йерене иҗарәйә учуз хаķ илә алмаķ мөмкин (آلمق ممكن) [Акъегет, 1886, б. 12]; Әлбәттә, аķча илә дә әбәди шөһрәт ķазанмаķ мөмкин (شهرت قزانمق ممكن), ... [Акъегет, 1886, б. 32]; Әрсезлек вә кискенлек илә һәр көн берәр капик тапсаң да, заман кәчмәсе илә баймамаķ мөхальдер (بايومماق محالدر) [Акъегет, 1886, б. 33–34]; Ул бер дәķиķаны да кире ķайтармаķ мөхаль (كيرو قايتارمق محال) [Акъегет, 1886, б. 64]; Уķымайы сәвмәк лязем (سومك لازم) дийү фикерләнә-фикерләнә Хисаметдин менла гәнә удасында гизмәйә башлады [Акъегет, 1886, б. 7]; Аны-буны алмаķ лязем була (آلمق لازوم بوله), кәндем килмәсәм, бәнем эшеме кем эшләсен? [Акъегет, 1886, б. 20]; Сәғәт күп икән, бәңа мәктүб йазмаķ кирәк (مكتوب يازمق كراك) [Акъегет, 1886, б. 23]; Инде әйт уғлыңа тутай, сабыр итмәк кирәк (صبر ايتمك كراك), бай безләрдән өстен буладыр [Акъегет, 1886, б. 52].

Иялек килешендә бу исем фигыльнең бары бер генә кулланылыш очрагы теркәлде: Эстәмәкнең (استماكنك) эстәмәге вар [Акъегет, 1886, б. 32].

Язучы *-маķ* кушымчалы исем фигыльләрне юнәлеш килешендә, нигездә, тартым кушымчаларыннан башка һәм түбәндәге рәвештә файдалана:

1) башлау фигыле белән бергә *-а* кушымчалы хәл фигыльләр урынында: Бу йирдә үзене забт идәмәйеп ағламаға башлады (اغلامغه باشلادى), үзе ағлыйур, үзе уķыйур [Акъегет, 1886, б. 6]; ...мәзкүр пычаķ илә ышпалеры йуаш-йуаш йармаға башлады (يارمغه باشلدى) [Акъегет, 1886, б. 10]; ...мәзкүр венгр татарча аķыртын бөйлә сөйләмәгә башлады (سويلمكه باشلدى)... [Акъегет, 1886, б. 27]; Түбән очдан йинә вә йинә мылтыķ атмаķлар ишеделмәгә башлады (ايشدولمكا باشلدى) [Акъегет, 1886, б. 52];

2) күчемле фигыльләр белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең кыек объектын күрсәтү өчен инфинитивның *-ырға* формасы урынында: Бундан бөйлә йәш әфәнде ķууҗыйа арабаны чана илә бәрабәрләтмәгә (برابرلتمكه) бойырып, менлайа хитабән сүзә бөйлә башлады [Акъегет, 1886, б. 8]; Һичбер инсан аңа ķаршы дор-

маға (قارشو دورمغه) җәсарәтләнмәз иде [Акъегет, 1886, б. 12]; Бинаән ғаләйһи бер-беремезнең табиғәтләре вә әхлақлары анлашылмадықча, җаwабы қатғый вирмәгә (ويرمكه) мөқтәдирә дәгелмен [Акъегет, 1886, б. 26] һ.б.;

3) хәрәкәт фигыльләре белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең башкарылу максатын ачыклау өчен инфинитивның *-ырга* формасы урынында: Ғали бай ғаиләсе илә чәй эчмәгә (چاى ايچمكه) утырмышкән, Бикбулат менла әфәнде керде [Акъегет, 1886, б. 12]; Кичәнең йарылары булғач, Мохтар мөсафирханәйә кичәләмәгә (كيچه لمكه) кәтде [Акъегет, 1886, б. 33]; Ничүн шадланмасын, қызыны мондай байға сурмаға (صورمغه) килделәр [Акъегет, 1886, б. 34].

Әсәрдә *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр юнәлеш килешендә тартым кушымчалары белән дә кулланылырга мөмкин. Бу очракта алар башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдереп киләләр: Шуның ичүн унбер сәғәтләрдән бирү менламыз бағҗадан ырақ дәгел бер базда ятып мәғшуқасының чықмағына (چقماغنه) мөнтәзыйр иде [Акъегет, 1886, б. 38]; Вәлхасыйль йәш қызның җегет илә тапышмақына (تاپشماقنه) кәндесене дә бераз сәбәбче сайдығындан мәрқүмә абыстай рәхәтсезләнеп нишләмәйә белмәде [Акъегет, 1886, б. 68].

Төшем килешендәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне автор башка эш-хәрәкәтнең туры объекты буларак файдалана: Бөйлә аҗы ағламағы (آغلامغى) ишедеп, анасы керер [Акъегет, 1886, б. 6]; Вә соранмақ-диләнмәкне (صورانمق ديلنمك نى) ғақылларына мотабик күреп, ... хәдисне инкяра қалқышдылар [Акъегет, 1886, б. 17]; Вә хис итде ки, йәш йөрәге қыз илә хәбәрләшмәге (خبرلشمكى), күрешмәк вә күз-күзә сүзләшмәге (سوزلشمكى) истийур [Акъегет, 1886, б. 21] һ.б.

Чыгыш килешендәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдерәләр: Қарйәнең әһалисе ике йөз әв қәдәр улып, адыны фаш итмәкдән (فاش ايتمكدن) чәкинийурыз, ... [Акъегет, 1886, б. 2]; Бунда Ғали байлар, Бикбулат менлалар Хисаметдин менла сүзләшмәкдән (سوزلشمكدن) қачып мәғлүб улды, дийү зийадә мәсрүр улдылар [Акъегет, 1886, б. 17]; Хөрмәтле уқуҗыларымның зиһенләрене арытмақдан (آروتمقدن) чәкенеп, хикәйәмнең ул қәдәр лязем улмайан тәфсиләтене йазмыйурым [Акъегет, 1886, б. 50].

Урын-вакыт килешендә бу исем фигыльнең бары бер генә кулланылыш очрагы теркәлде: ...Ғайниҗамал абыстасының инсанийәтенә арқа вireп, йәш қыз мөтәсәлле улды вә иләре җөрмәгендә (جورمكنده) дәвам итде [Акъегет, 1886, б. 57].

«Хисаметдин менла» романында *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр өчен *ичүн* (ايچون) һәм *илә* (ايله) бәйлекләре белән кулланылу хас. *-мак ичүн* конструкциясенә язучы башка эш-хәрәкәтнең башкарылу максатын яисә сәбәбен тасвирлаганда мөрәҗәгать итә: ...анҗақ хикәйәмезе йиңел аңлатмақ ичүн (آكلاتمق ايچون) адыны «Нун» хәрефе илә ишарәт идәмез [Акъегет, 1886, б. 2]; Җомға намазыны уқыдықдан соңра Хисаметдин менла атны чанайа йигеп, бәғзе кирәк шәйләр алмақ ичүн (المق ايچون) шәһәрә йулланды [Акъегет, 1886, б. 7]; Қараwыллық җәһәтендә булынан Хәнифә туташ менланың сүзләрене ишедеп мәмнун улды вә үз җенесе улан қадынлар хақында даха мәғлүмат хасыйл итмәк ичүн (حاصل ايتمك ايچون) диққәтене артдырып қолақларыны мөсафирлек бүлмәсенә салды [Акъегет, 1886, б. 11].

*-мак илә* конструкциясе әсәрдә башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдерү өчен кулланыла: Мәзкүр бүлмәсендән мөсафирлек бүлмәсенә бер йарық йасады вә шу йарықдан йегет менлайы бақмақ илә (باقمق ايله) хушланыр [Акъегет, 1886, б. 10]; ...шимди исә бер күрмәк илә (كورمكله) қәнәғәтләнмәйеп, мorады дәһа артды [Акъегет, 1886, б. 21]; Чүнкә қуәтле вә мөхкәм ғыйшық бер-беремезнең тыш вә заһири күренешемезне белмәк илә (بلمكله) хосулә килмәз, сез заһиремне йаратдыңыз [Акъегет, 1886, б. 25–26].

Моннан тыш, чыганакта *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрнең, *ғайре* (غيرى) һәм *мағада* (ماعدا) бәйлекләре белән кулланылу очраклары да теркәлде: Буның кеби мөдәрисләрдә тәзйиғе ғөмер идеп, шәкердлек идеп, қычқырышмақдан ғайре (قچقروشمقدن غيرى) бер шәй тәхсил улынмыйдыр [Акъегет, 1886, б. 18]; Белешемез Хисаметдин менла сыйбийан уқытмақдан мағада (اوقونماقندن ماعدا) арыш вә солыларыны суқтырып вә сатып кәсеб идеп эшсез һич ятмаз иде [Акъегет, 1886, б. 19].

З. Бигиев әсәрләрендә *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрнең, нигездә, тартым кушымчаларыннан башка баш, юнәлеш, төшем һәм чыгыш килешләрендә кулланылулары күзәтелә. Баш килештә әлеге исем фигыльләр аерым бер зат тарафыннан башкарылган эш-хәрәкәтне яисә аның белән бәйле вақыйганы атап киләләр: Хатыннарның чуқ йығламақы (يغلامقى) ғади шәйдер [Бигиев, 1887, б. 67]; Мәхәббәтле әткәйем тәрке дөнйа қылдығы сәбәбе илә сезнең мәҗрух улан күңелеңезә бәнем сезне тәрке қылып қачмақым (قاچماقم) зәһәрдер [Бигиев, 1887, б. 68]; Бөйләҗә сөйләшеп унбиш-йегерме дәкиқа эчендә йәмәк вә эчмәк (يمك و اچمك) тәмам улғач, мөсафирләремез садақаларын виреп, имам әфәнде ивендән китделәр [Бигиев, 1890, б. 5]; Бөйлә йоқылара уғра-

мыш адәмләр, үлмеш адәм кеби улып, һич дә хәйәт әсәрләре – нәфәс алмақ, пульс тамырлар тибмәк (نفس آلمق پولس تامورلر تبمك) қалмайдыр [Бигиев, 1890, б. 58]; ...у wақыт у тарафлары зийарәт итмәк (زيارت ايتمك) бик ағыр, ғайәт мөшкел иде [Бигиев, 1908, б. 1]; Бурада яңа килмеш мәғлүм бер адәме дәғвәт қылып, зыйафәт вирмәк (ضيافت ويرمك) бер ғәдәт имеш [Бигиев, 1908, б. 70].

Автор баш килештәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне исем сүзтезмәләр составында атрибутив позициядә дә куллана: Күп кешеләрнең ривайәтенә бинаән Муса Салихов заграницайа қачмақ (قاچمق) тәдарекендәдер [Бигиев, 1887, б. 31–32]; Ғабденнәсыр әфәнде, номеренә қайтқач, чәй эчмәк (چاى اچمك) мақсуды илә хадимдән самавар таләб итәдер [Бигиев, 1887, б. 54]; Җиһангир Ағийев, хикәйәмезнең героинясе Маһруй қызның ғыйрфанына хәйран вә хөсненә ғашыйқ улып, қызы никях идеп алмақ (آلمق) фикеренә килеп, ... [Бигиев, 1890, б. 8]; Ниһайәтсез саран-бәхил вә хасид кемсәнәләр улып, абыхәйәт эчәнләр кеби, төн-көн җәлбе дөнйа – мал артдырмақ (مال آرتدرمق) қайғысында улып, ... [Бигиев, 1890, б. 10]; ...уйқуда улан бичаралары уйғатмақ (اويغاتمق) қасды илә, ханә қапысына килдек [Бигиев, 1908, б. 19]; Ғаскәрийәтдән қачмақ (قاچمق) фикере башыма килмәмеш, һич килмәйәчәкдер [Бигиев, 1908, б. 25].

Чыганакларда баш килештәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр аерым очракларда, *мөмкин* (ممكن), *лязем* (لازم) модаль сүзләре белән бергә килеп, инфинитивның *-ырға* формасы урынында да кулланылалар: Гәрчә йыртқаланмыш улса да, сурәт әҗзаларыны ба тәртиб җәмғ қылып қаралса, нә шәкелле сурәт идегене аңламақ мөмкин (آنكلامق ممكن) [Бигиев, 1887, б. 7]; Шимди тәфтишчеләргә қатил Мусаны эзләп табмақ лязем улып (ازلب طابماق لازم اولوب), ... [Бигиев, 1887, б. 8]; Берқач сәғәт поездны бәкләмәк лязем иде (بكله مك لازم ايدى) [Бигиев, 1887, б. 42].

Язучы *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне юнәлеш килешендә, нигездә тартым кушымчаларыннан башка гына һәм түбәндәге рәвештә файдалана:

1) *башла-* фигыле белән бергә *-а* кушымчалы хәл фигыльләр урынында: ...тәфтишчеләр номерә эчендәге әшьяйы қарамаға башладылар (قراماغه باشلاديلر) [Бигиев, 1887, б. 7]; Муса әфәнде ғаҗәлә қылып, ... гәзитәйе бақмаға башлады (باقمغه باشلادى) [Бигиев, 1887, б. 36]; Номерләр сахибе Ғабдуллин килгәч, господин прокурор Ғабдуллиндан бу тариқа сөаль қылмаға башлады (سوءال قيلماغه باشلادى) ... [Бигиев, 1887, б. 43–44];

2) күчемле фигыльләр белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең кыек объектын күрсәтү өчен инфинитивның *-ырға* формасы урынында: Судебный следователь бу тариқа тәфтиш қылмаға (تفتيش قيلماغه) шөруғ қылды... [Бигиев, 1887, б. 5]; ...сез ғазизләремезә бер-ике сәтрә мәктүб йазмаға (يازمغه) жөрьәт идейурмын [Бигиев, 1887, б. 35]; Маһруйны да йазмаға вә уқымаға (يازمغه و اوقومغه) мән үгрәтдем [Бигиев, 1890, б. 29];

3) хәрәкәт фигыльләре белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең башкарылу максатын ачыклау өчен инфинитивның *-ырға* формасы урынында: Тарафындән дә тәкәллем тәмам улғач, присяжный заседательләр ... икенче бүлмәйә иттифақ қылмаға (اتفاق قيلماغه) китделәр [Бигиев, 1887, б. 46]; Господин Иванов, йирендән торып, өстәлдәге кәғәзне қарамаға (قاراماغه) килеп, ... [Бигиев, 1887, б. 61].

Төшем килешендәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне автор башка эш-хәрәкәтнең туры объекты буларак файдалана: ...тәкә төрекмәнләре, зарурәт хәлендә билә дошман әленә тәслим улынмағы (تسليم اولنمغى) қабул итмәйеп, ... [Бигиев, 1908, б. 51–52]; Ходайа махсус улан қыйам һәм рөкүгы бер инсан мәркәденә тәкдим итмәге (تقديم ايتمگى) қалебем тәхәммел идәмәде [Бигиев, 1908, б. 86]; Фәқирлекдән ғаҗиз қалмыш шәкерд ғыйлем таләб итмәге (طلب ايتمگى) тәрк идәр, ... [Бигиев, 1908, б. 102].

Чыгыш килешендәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдерәләр: Көндезләрдә, ғазизем Муса әфәнде, зиһенемдә сезе йөрәк бәғрем тәсаувыр идеп зәwеқләнмәкдән (ذوقلنمقدن) үз-үземне мәнғыйа тәқәтем қалмадығындан... [Бигиев, 1887, б. 35]; ...Қазанға килән wақытда байның фатихасыны ... алмақдан (آلمقدن) ғафил улмайынча, һәрwақыт, хәтта Мәкәрҗә базарында да байны зийарәт қыладыр иде [Бигиев, 1890, б. 9]; Ике йә өч көн мөқәддәм әҗәлене эзләп, Маһруй муйынына питлә қуймыш исә дә, шимди үлмәкдән (اولمكدن) ғайәт дә қурықмайа башлады [Бигиев, 1890, б. 55]; Ғоләмәи исламың мәғәриф юлында хезмәтләре аңланмаз мәтен, аңлатмаз шөрух йазмақдан (يازمقدن) ғибәрәт улды [Бигиев, 1908, б. 10]; Мәҗлесләре хайwан кеби йимәкдән (ييمك دن), бере-бере илә талашмақдан (طالاشمق دن) ғибәрәт улыр [Бигиев, 1908, б. 26] һ.б.

Урын-вакыт килешендә бу исем фигыльнең бары бер генә кулланылыш очрагы теркәлде: ...төрекмәнләрең йәшләре-қартлары ат бенмәкдә (آت بنمك ده), силах кулланмакда (سلاح قوللانمقده) ғайәт маһир улыр [Бигиев, 1908, б. 45].

З. Бигиев әсәрләрендә *-мак* кушымчалы исем фигыльләргә *өчен* (اوچون) / *ичүн* (ایچون) һәм *илә* (ایله) бәйлекләре белән кулланылу хас. *-мак өчен/ичүн* конструкциясенә язучы башка эш-хәрәкәтнең башкарылу максатын яисә сәбәбен тасвирлаганда мөрәҗәгать итә: Господин Шубин күстәрелмеш йиргә ултырып сәламәтлек сорашкач, Муса әфәнде кунакны хөрмәтләмәк өчен (حرمتلمك اوچون) хадимгә чәй килтерергә кушды [Бигиев, 1887, б. 11]; ...иртә намаз wакытында Әхмәди бай, Нигъмәтулла әфәнде, Габденнасыр әфәнде, господин Андреев Муса әфәнденең хәлене белмәк өчен (حلنی بلمك اوچون) хәбесханәйә килеп, ... [Бигиев, 1887, б. 33–34]; Шимди исә йимәк-эчмәк ичүн (یمك اچمك ایچون) Җиһангир Агиев, бер чәйханәйә кереп, лязем шәйләре сорап, ашап-эчеп утырадыр [Бигиев, 1890, б. 36]; ...җепнең икенче тарафыны бағламак ичүн (باغلماق ایچون), «секретный» бүлмәсенең стенасындан бер гвоздь (шип) йукмы икән дийү, кичә караңгы улдыгы сәбәбдән кул илә эзләмәйә башламыш улса да, җебнең икенче тарафыны бағламайа бер шәй дә таба алмады [Бигиев, 1890, б. 40]; Эшнең асылыны аңламак өчен (آکلامق ایچون) арабымы туктатдым [Бигиев, 1908, б. 19]; Шәһәр урыныны корытмак ичүн (قوروتمق ایچون) 1744 сәнәдә ибтида улынмыш, ләкин парә йуклык сәбәбле тәрк улынмыш [Бигиев, 1908, б. 32] һ.б.

*-мак илә* конструкциясе чыганакларда түбәндәге рәвештә кулланыла: Бер йарык табды вә шу йарыкдан Муса әфәндейе күрмәк илә (کورمك ایله) Хәдичә туташ бәхтийәр улды [Бигиев, 1887, б. 33]; Хасыйле кәлям, Хәдичә туташ Муса әфәнденең шәҗагәтле вә күркәм йөзенә карамак илә (قرامق ایله) Камал ләззәт илә ләззәтләнер иде [Бигиев, 1887, б. 33]; Мөкәддәм керәнләр мәхкәмәнең бүйүк залында улан ағач эскәмияләрнең алдагы софуфларына ултырмак илә (اولترمق ایله) бәхтийәр улдылар [Бигиев, 1887, б. 37]; Асыл ватанларында калабелмеш төрекмәнләр иң соң заманлара кәдәр бәдәвият хәлендә, сахрада мал, хайwан тәрбийә итмәк илә (تربیه ایتمکله) мәгишәт идәрләр [Бигиев, 1908, б. 44].

Р. Фәхретдин әсәрләрендә *-мак* кушымчалы исем фигыльләр тартым кушымчалары белән бергә һәм алардан башка барлык килешләрдә дә кулланылалар. Баш килештә әлеге исем фигыльләр аерым бер зат тарафыннан башкарылган эш-хәрәкәтне яисә аның белән бәйле вакыйганы атап киләләр: Анлар хакында әйтдем дә, аңламадылар яки кәдеремне белмәделәр дип, үпкә идеп, бер читкә чыкмак (چیتکا چقمق) һәм гайеб гөнаһдыр [Фәхретдин, 1899, б. 6]; Бунларның каберләренә варып дәрйа мисалында күз йәшләремне акызып йыгламак (یغلامق),

бәнем ичүн дөнйада беренче шадлық хисаб иделмәкдә иде [Фәхретдин, 1899, б. 7]; Бу кеби шәйләр илә шөбһәләнмәк (شبه لنمك) адәм баласына йөрәксезлек, қурқақлық китереп, ахырында бер төрле хыйал пәйда улмақына сәбәб уладыр [Фәхретдин, 1899, б. 9]; Халықларың һөнәрләрене, милли әсәрләрене қыйммәтсез қалдырмақ (قالدرمق) мәдәнийәтсез қаwемләрдә улса да, мәдәнийәтле, хасийәтле, йомшақ күнелле қаwемләр бөйлә дәгелдер [Фәхретдин, 1903, б. 26]; Акробатлар рәwешендә йөзләренә буйамыш ақ вә қызыл буйаулары, әдәбсез сөйләшмәкләре (سويلشمكلرى), килешсез күренешләре күңелләрә бер рәхәтсезлек, бәлки хәсрәт китермәкдә иде [Фәхретдин, 1903, б. 60] һ.б.

Автор баш килештәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне исем сүзтезмәләр составында атрибутив позициядә дә куллана: Бу түбәнлек соңы әлбәттә харабльқдыр, ләкин хәлемезне тәғмир итмәк вә төзәтмәк (تعمير ايتمك و توزاتمك) заманы да кәчмәмешдер [Фәхретдин, 1899, б. 10]; Сәүдә вә мал кәсеб итмәк (مال كسب ايتمك) туғрысында баһадир ғаскәрләр кеби алдан йөрерләр иде [Фәхретдин, 1899, б. 11]; Ләкин Ғаббас мелланы қулдан йибәрмәк эстәмәдеге хәлдә берқәдәр назланмақ вә ялындырмақ (نازلنمق و يالندرمق) фикерендә иде [Фәхретдин, 1903, б. 17]; Исерткеч эчмәк (ايچمك) йулыны халықға күстәрә вә йәш егетләр арасында фәсаде әхлақ нәшер идә, дийә ишедер идем [Фәхретдин, 1903, б. 29] һ.б.

Чыганакларда баш килештәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр III зат хәбәрлек кушымчасын алган хәлдә предикатив позициядә дә теркәлде: Шөкерләр улсун, бу көн тәхсилеме тәмам итдем, морадым да үз халқымызға хезмәт итмәкдер (خدمت ايتمكدر) [Фәхретдин, 1899, б. 24]; ...безем (мөғаллим вә хәлфәләр) хезмәтемез балаларың ғөмерләре заиғ улмаз рәвешчә Җәнабе Аллаһың ризалығыны өмид идеп уқытмақдыр (اوقوتمقدر) [Фәхретдин, 1903, б. 7–8]; Бәндәнең бурычы исә иҗтиһад вә ғайрәт һәм Җәнабе Аллаһ ризасы ичүн ғайрәт итмәкдер (غيرت ايتمكدر) [Фәхретдин, 1899, б. 43].

Шуның белән бергә Р. Фәхретдин әсәрләрендә баш килештәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр эзлекле рәвештә инфинитивның *-ырға* кушымчалы формасы урынында да кулланылалар. Бу түбәндәге очракларда күзәтелә:

1) *эстә-* фигыле белән бергә кулланылганда: Йосыф бабай ғайәт тә садә дил (саф күңелле), берқатлы адәм улып, ...Хәмидәнең җөмлә сүзенә ышанып, Әсманы күңел вә хәтер ачып килсен дия йибәрмәк эстәр иде (يبارمك استر ايدى) [Фәхретдин, 1903, б. 57]; Салих бай

вә хатыны исә мөғәллим әфәндегә вирмәйә қамил дәрәҗә арзу итдекләре хәлдә, мөғәллимәнең кәнде күңелене белмәк эстәрләр иде (بیلمك استرلر ایدی) [Фәхретдин, 1903, б. 109]; Күзенә ышанмақ эстәмәде исә дә (اشانمق استمدی ایسه ده), йақын улан забитдан (городовой) сордығында,... [Фәхретдин, 1903, б. 125];

2) *ул-* ярдәмче фигыле белән бергә килгәндә: Ошбу соңғы затлар ичүн дийә без дә бу әсәремезне нәшер итмәк (نشر ایتمك) улдық [Фәхретдин, 1899, б. 2]; Төркийә, Мисыр мәмләкәтләренә йөрмәк (یورمك), Қытай вә Йапун өлкәләрене күрмәк (كورمك), Һиндстан вә Җава туфрақларыны зийарәт итмәк уладыр идем (زیارت ایتمك اوله در ایدم) [Фәхретдин, 1899, б. 7]; Ғаббас мелланы сәүдегендән Алла ризасы ичүн тәрбийә идеп, асрамақ улды (آسرامق اولدی) [Фәхретдин, 1903, б. 45]; Бән дә буны форсат билеп, хәзрәтләр илә күрешмәк улдым (كورشمك اولدم) [Фәхретдин, 1903, б. 79] һ.б.;

3) *лязем* (لازم) модаль сүзе белән бергә кулланылганда: Ахирәт ичүн – йалгыз дин ғилме, дөнйа тормышы ичүн дин илә дөнйа ғилмене һәм белмәк ляземдер (بیلمك لازمدر) [Фәхретдин, 1899, б. 5]; Хәлбуки анларға хезмәт итмәк ичүн иң элек мәхәббәтләрене кәсеб итмәк ляземдер (كثب ایتمك لازمدر) [Фәхретдин, 1899, б. 5]; Зира дәрд вә хәсрәт әхелләрене тәслийә итмәк ичүн күп затларың тәрҗемәи хәлләрене белмәк (بیلمك) вә анлары мисал идәрәк күстәрмәк ляземдер (كوسترمك لازمدر) [Фәхретдин, 1903, б. 53]; Мәдрәсә низамларына күрә ошбу сәғәтдә қалқып китмәк (كتمك) лязем иде [Фәхретдин, 1903, б. 55];

4) *тийеш ул-* (تیوش اول) тезмә фигыле белән бергә кулланылганда: Хосусан бу көнгә бик йақын бер заманда йазылған китабларны күрмәк тийеш улыр (كورمك تیوش اولور) [Фәхретдин, 1899, б. 59]; Алай исә уқытмақ да тийеш улмаз (اوقتمقده تیوش اولماز), чөнки уқырға белсәләр, йегетләр йазған хатларны уқырлар [Фәхретдин, 1899, б. 65]; Шу сәбәбле балаларны сабый wақытларында йахшы тәрбийә итмәк (تربیه ایتمك) вә ислам әдәбләре илә әдәбләндермәк тийешледер (ادبلندرمك تیوشلیدر) [Фәхретдин, 1899, б. 67]; Ғәмәлләр вә хезмәтләр бөйлә тәқсим иделенеп, һәркем үз хезмәтене белеп Камал әйләмәк хақында ғайрәт әйләмәк тийешле улыр (غیرت ایلمك تیوشلی اولور) [Фәхретдин, 1903, б. 8];

5) *мөмкин* (ممكن) модаль сүзе белән бергә килгәндә: Бу хосусда чит халықлардан ғибрәт алмақ мөмкин исә дә (عبرت آلمق ممكن ایسه ده), ... [Фәхретдин, 1899, б. 10]; Бу делләр сәбәбендән кирәк Россиядә, кирәк Йаурупа вә Америкада, кирәк Иран, Әфған, Һинд тарафларында сәүдә итмәк мөмкин улачақдыр (سودا ایتمك ممكن اوله چقدر) [Фәхретдин,

1899, б. 13]; Әгәр дә сөйләр исә, Ғаббас мелланың нә ки сәбәбә бинаән кәтдегене Ғайшә абыстайдан аңламак мөмкин иде (آڭلامق ممكن ايدى) [Фәхретдин, 1903, б. 40]; Анлара қаршы сүз сөйләмәк (سوز سويلمك) вә бер-бер төрле фикер ғарыз итмәк асла мөмкин улмаз (فكر عرض ايتمك اثلا ممكن اولماز) [Фәхретдин, 1903, б. 62] һ.б.;

6) *мөйәссәр ул-* (ميسر اول) фигыле белән бергә кулланылганда: Бу рәхәтләрне күрмәк мөйәссәр улырмы (كورمك ميسر اولورمى)... [Фәхретдин, 1899, б. 8]; Бәлки дөнйалықда сезнең илә күрешмәк мөйәссәр улмаз (كورشمك ميسر اولماز), ... [Фәхретдин, 1899, б. 13]; Шулай исә дә, шатлық хәбәрләрне ишетмәк мөйәссәр улса иде (ايشتمك ميسر اولسه ايدى)!.. [Фәхретдин, 1899, б. 78].

Иялек килешендә әлеге исем фигыльләр исем сүзтезмәләр составында атрибутив позициядә киләләр: Ата улмақның (آتا اولمقنڭ) wазыйфасы да балаларға йул күстәрмәк вә хаҗәтләрене үгрәтмәкдер [Фәхретдин, 1899, б. 10]; Әсманың бу ике хәлене фикерләп, истикбале хақында бер фикер йөретмәгең (يورتمكك) урыны хикәйәнең ошбу йирендә улса кирәк [Фәхретдин, 1899, б. 48].

Язучы юнәлеш килешендәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне, күчемле фигыльләр белән бергә, алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең кыек объектын күрсәтү өчен *-у* кушымчалы исем фигыльләре һәм инфинитивның *-ырға* формасы урынында куллана: Қурқуның сәбәбе исә, анлар илә сүзләшмәк лязем улдығында ғарәбчә дөрест сүзләмәгемә (سوزلمكمه) ышанычым улмадығы иде [Фәхретдин, 1899, б. 19]; Қайғы хәбәрене ишетмәкгә (ايشتمككگا) нисбәт әйләдекдә, шадлық хәбәрене ишетмәк ағыр һәм гүч улдығыны белдем [Фәхретдин, 1899, б. 78]; Мәғлүмдер ки, баланың дәресендән алачақ файдасы, үзенең күңеле арзу идеп, хозур вә кәйеф үзәрендә уқымағына (اوقومغنه) бағлыдыр [Фәхретдин, 1903, б. 13]; Бунлар исә милләтең бай булмақына (باى بولمقنه), дин илә дөнйалары кечеләнмәгенә (كوچلنمكنه) сәбәб улыр [Фәхретдин, 1903, б. 94].

М. Акъегет һәм З. Бигиев әсәрләреннән аермалы буларақ, Р. Фәхретдин романнарында юнәлеш килешендәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр башка мәгънәләрдә теркәлмәде.

Төшем килешендәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне автор башка эш-хәрәкәтнең туры объекты буларак файдалана: Пароход хезмәтчеләренең ашығып нәрсә ташулары, яғмур күрелгәндә ашлық уручыларның йөгерә-йөгерә көлтә җыймақларыны (جيمقلرنى) искә төшерә иде [Фәхретдин, 1899, б. 14]; Буңа мәрхәмәт итмәкне

(مرحمت ایتمکنی) инсанлыгым җәһәтендән үземә бер лязем эш дийә хисаб итдем [Фәхретдин, 1899, б. 18]; ...һәм бөйлә димәге (دیمکی) асла белмәзләр, дөнйада бөйлә сүзләр вә бөйлә тәгбирләр вар идегендән дә хәбәрдар дәгелләр иде [Фәхретдин, 1903, б. 54]; ...мәхәллә әхелендән бәгзе мөгтәбәр кемсәләрә хәбәр йибәреп аз wакытга бәнем хозурыма килмәкләрене (کلمکلرنی) үтендем [Фәхретдин, 1903, б. 79].

Чыгыш килешендәге *-мак* кушымчалы исем фигыльләр башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдерәләр: Дүртенчемез, байлар хәтерене калдырмаз ичүн, лязем wәгәзләрне әйтмәкдән (ایتمکدن) сөкүт итде [Фәхретдин, 1899, б. 12]; ...әмма бу сәгәтдә исә «миллийәт кийем сакламакдан (ساقلامقدن) гибәрәт дәгел, бәлки барлыкны сакламакдан гибәрәт» димәкдә идем [Фәхретдин, 1899, б. 31]; Габбас мелланың игтикадына күрә сәгәдәт йорт, йир, керем, салым, ат, тундан гибәрәт улмай, бәлки өст бөтен, тамак тук, җан тыныч улмакдан (طنچ اولمقدن) гибәрәт иде [Фәхретдин, 1903, б. 10]; Бәгзеләре Хикмәт хаҗи тарафындан ут салыначак дарының күтәрелмәгендән (کوتارلمکندن) куркып китде, ... [Фәхретдин, 1903, б. 40].

М. Акьегет һәм З. Бигиев әсәрләреннән аермалы буларак, Р. Фәхретдин романнарында *-мак* кушымчалы исем фигыльләр урынвакыт килешендә дә еш кулланылалар: Wакыт үткән соңында үкенмәкдә (اوکنمکده) бер файда йукдыр [Фәхретдин, 1899, б. 20]; Кагыйдәсез укымакда (اوقومقده), низамсыз мәдрәсәдә йатмакда (یاتمقده) күкрәк бозмак, зиһен wатмакдан башка файда йук идеге бәңа бу хәлдә мәгълүм улды [Фәхретдин, 1899, б. 21]; Шуның ичүн бәгзе wакыт күңеле истирахәт итдермәкдә (استراحت ایتدرمکده) зарар улмаз [Фәхретдин, 1903, б. 10]; Бунлар үзләренең балаларыны бөйлә бер тырышлык илә тәрбийә итдекләре ичүн, бөйлә олуг өмидләр итмәкдә (امیدلر ایتمکده) хаксыз дәгелләр иде [Фәхретдин, 1903, б. 15] һ.б.

Р. Фәхретдин романнарында *-мак* кушымчалы исем фигыльләргә *ичүн* (ایچون), *кеби* (کبی), *кадәр* (قدر) һәм *илә* (ایله) бәйлекләре белән кулланылу хас. *-мак ичүн* конструкциясенә язучы башка эш-хәрәкәтнең башкарылу максатын яисә сәбәбен тасвирлаганда мөрәҗәгать итә: ...күпләре пароход озатмак бәһанәсе илә беләзек илә алкаларыны, күлмәк илә зонтикларыны вә йаңа мода эшләпәләрене күстәрмәк ичүн (کوسترمك ایچون), әлхасыйль, күрмәкдән артык, күрелмәк ичүн (کورلمك ایچون) килдекләре заһир иде [Фәхретдин, 1899, б. 15]; Көннең хушлыгындан, һаwаның рәхәтлегендән файдаланмак ичүн (فایده لنمق ایچون) пароход халкы урынларындан чыкып варалар иде

[Фәхретдин, 1899, б. 22]; ...вә венгр лисаны илә башқорд лисаны арасында улан мөнәсәбәтләре белмәк ичүн (بیلمك ایچون) башқорт лисаныны үгрәнмәкдә иде [Фәхретдин, 1903, б. 50]; ...вә Әсманы һәм «Ф...» шәһәренә бер-ике ай мөддәтә қунақға алып китмәк ичүн (آلوب كتمك ایچون) бунда туқталдығыны бәйан әйләде [Фәхретдин, 1903, б. 56] һ.б.

*-мак кеби* (а) һәм *-мак қәдәр* (ә) конструкцияләрен автор чагыштыруларда файдалана:

а) ...фазыл әһелләренең хөрмәтләрене йиренә килтермәк кеби (یرینه كلتورمك كبی) бер Камаләт һәрбер кемсәнәдә табылыр исә, белгән илә белмәгән арасында һичбер айырма улмай, җөмлә адәм баласы бер тигез улмыш улыр иде [Фәхретдин, 1899, б. 6]; Йалңыз бер қызымны йырақ урынларға йибәреб уқытмақ кеби (اوقوتمق كبی) читен эшләргә вә фирақ хәсрәтләренә сабыр иткән вә түзгән идем ... [Фәхретдин, 1899, б. 35]; Дөнйада бәгзе кемсәләр улыр ки, рәхәте сәфәхәтханәләрдән вә шадлығы да төнозын қомарханәләрдә утырмақ кеби (اوطورمق كبی) шәйләрдән эзләрләр [Фәхретдин, 1903, б. 14];

ә) Әмма үзенә махсус тегелмәгән күлмәк илә туйға вармақ қәдәр (وارمق قدر) олуғ ғайеб һич улынмаз... [Фәхретдин, 1899, б. 64]; Исерткеч эчмәк – ағу эчмәк қәдәр (ایچمك قدر) зәһәрле вә һәртөрле хасталықларың баш сәбәбе идегене бер доктордан ишедеп тәмам қәнәғәт әйләмеш иде [Фәхретдин, 1903, б. 23]; Хәсрәтле кемсә ичүн кәндесе кеби вә йә кәндесендән зийадә ағыр бер хәлдә улан кемсәйе күрмәк қәдәр (كورمك قدر) файдалы шәй йукдыр [Фәхретдин, 1903, б. 53].

*-мак илә* конструкциясе әсәрләрдә башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдерү өчен кулланыла: Милләтне мәсғүд итмәк исә, анларға йиңел уқымақ вә гүзәл кәсеб идеп байлық тапмақ йулларыны күстәрмәк илә (كوسترمك ایله), һөнәр вә сәнғәтләр белдермәк илә (بیلدرمك ایله) улыр [Фәхретдин, 1899, б. 6]; Бәгзе бер кемсәнәләрнең, үзләренең ир җенесендән улмақлары илә (ایر جنسندن اولمقلری ایله) мәдехләнеп, хатынларны кимсетеп сүзләдекләрене хәтерләп, ... [Фәхретдин, 1899, б. 21]; Бунларың уқытмақ илә (اوقوتمق ایله) мәшғүл улмаған кемсәләрә бер сүзләре улмадығы хәлдә, уқытучылар туғрысында йөз төрле сүзләре улмақдадыр!... [Фәхретдин, 1903, б. 38]; Күзене йомдығы илә кәндене мәктәбдә күрер, төн барынча мәктәб вә уқымақ илә (اوقومقله) саташып чықар иде [Фәхретдин, 1903, б. 75].

Ф. Кәрими сәяхәтнамәләрендә *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр тартым кушымчалары белән төрләнмәгән хәлдә баш, юнәлеш, төшем, чыгыш һәм урын-вакыт килешләрендә кулланылалар. Баш ки-

лештә әлеге исем фигыльләр аерым бер зат тарафыннан башкарылган эш-хәрәкәтне яисә аның белән бәйле вакыйганы атап киләләр: Бәйнәлмиләл йатақлы вагонлар пәк мөкәммәл исә дә, фийатлары зийадәсе илә йуқсәк улдығындан, анлар илә гизмәк (كزمك) һәркәс ичүн мөмкин улмыйур [Кәрими, 1902, б. 7]; Әлфаз илә уғрашмақ (اوغراشمق) бездә пәк әскидән ғәдәт улып қалмыщдыр [Кәрими, 1902, б. 36]; Безем кеби дел билмәйәнләр ичүн бурада wақыт кичермәк (وقت كچرمك) қулай улды [Кәрими, 1902, б. 80]; ...мөхәррирене тәбрик вә хөсне хезмәтенә тәшәккер итмәк (تشكر ايتمك) бурычымыз иде [Кәрими, 1908, б. 3] һ.б.

Автор баш килештәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне исем сүзтезмәләр составында атрибутив позициядә дә куллана: ...һәркәсең дөнйайы сәвәрәк, мөмкин мәртәбә зийадәҗә йәшәмәк (ياشامق) арзусында улынмасы даха зийадә тәғәҗҗеб улынаҗақ бер шәйдер [Кәрими, 1902, б. 9]; Шакир әфәнде кәнде алтын эшләре ичүн бер тақым аләтләр алмақ (آلمق) фикерендә иде [Кәрими, 1902, б. 10]; ...аз wақыт улса да бунлар илә күрешеп китмәк (كوريشوب كيتمك) мақсады илә Оренбургдан нә wақыт чығаҗағымызы бер ачық хат илә әүwәлдән хәбәр виреп қуймыш идем [Кәрими, 1908, б. 8]; Зан идәрем ки, күп хатын алмақ (آلمق), хатынлары талақ итмәк (طلاق ايتمك) вә анларны даимән қачырып тотмақ (قاچروب طوتمق) хосусларында һәм шимдики мөселманлар шәриғәтеңезе суи истиғмаль идийурлардыр [Кәрими, 1908, б. 21] һ.б.

Чыганакларда баш килештәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр предикатив позициядә дә очрыйлар: Wақыт хәйәтләрендә французлар ичүн әң бүйүк рөтбә Ақадемияйә әғзә улмақдыр (اغضا اولمقدر) [Кәрими, 1902, б. 128]; Мақсадымыз буны күрмәк иде (كورمك ايدى) [Кәрими, 1902, б. 128]; Бағчасарайың башлыҗа тиҗарәте вә һөнәре сафийандан хатын вә қызлар ичүн айақ қаблары, вә хатынлар ичүн баш өртүсе йапмақ вә дире эшләмәкдер (ياپمق و درى ايشلمكدر) [Кәрими, 1908, б. 60].

Шуның белән бергә, Ф. Кәрими әсәрләрендә баш килештәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр эзлекле рәвештә инфинитивның *-ырға* формасын алыштырып киләләр. Бу түбәндәге очракларда күзәтелә:

1) *эстә-* фигыле белән бергә кулланылганда: ...ханги милләте күрмәк эстәрсәң (كورمك ايسترسه ڭ), бурададыр [Кәрими, 1902, б. 8]; Шакир әфәнде кәнде алтын мәғдәнләрендә эшләтмәк ичүн локомобиль (паровой машина) вә саир аләтләр алмақ эстийур иде (آلمق ايستيور ايدى) [Кәрими, 1902, б. 19]; Сәйр итмәк эстәйән (سير ايتمك ايستيان) адәмләр сәғәт берә қәдәр тупланып көтебханәнең дахилендә бәклийурлар [Кәрими, 1902, б. 42] һ.б.;

2) *лязем* (لازم) модаль сүзе белән бергә кулланылганда: Сәфәрә чыкмаздан әүwәл йул ичүн бәғзе хәзерлек күрмәк лязем улдығы (كورمك لازم اولديغى) һәркәсә мәғлүмдер [Кәрими, 1902, б. 2]; Чүнкә бу отельдә йир булынмаса да, башкасына бу хаммал илә вармақ мөмкин улмайаҗақ, бәлки араба тотмақ лязем киләҗәкдер (آرابه طوتمق لازم كله جكدر) [Кәрими, 1902, б. 64]; Бурасыны сәйр итмәк ичүн махсус даирәдән билет алмақ лязем дер (آلمق لازمدر) [Кәрими, 1902, б. 127–128]; ...пашпурт вә саир һәр дөрлү хаҗәт эшләр ичүн извощик илә хөкүмәт даирәләренә тус-туғры кәнделәре вармақ лязем дер (وارمق لازمدر) [Кәрими, 1908, б. 91];

3) *мөмкин* (ممكن) модаль сүзе белән бергә килгәндә: Мөсафирханәләр тарафындан вокзаллара күндәрелән бу арабалар эчәресенә сигез-ун кеше утырмақ мөмкиндер (اوطورمق ممكندر) [Кәрими, 1902, б. 11]; Хәтта лисанлары беленмәсә дә уйнадықларыны аңламақ мөмкиндер (آڭلامق ممكندر) [Кәрими, 1902, б. 37]; Бунлардан пәк чуқ фикер вә ғибрәт алмақ мөмкиндер (عبرت آلمق ممكندر) [Кәрими, 1908, б. 40]; Бурада дәһа қалмақ вә мәктәбе тәдриҗән дәһа тәрәққый итдермәк пәк мөмкин иде (ترقى ايتديرمك پك ممكن ايدى) [Кәрими, 1908, б. 105]; Қырымда табиғатең гүзәллегенә даир пәк чуқ шәйләр йазмақ мөмкиндер (يازمق ممكندر) [Кәрими, 1908, б. 116].

Язучы *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне юнәлеш килешендә, нигездә, тартым кушымчаларыннан башка гына һәм түбәндәге рәвештә файдалана:

1) *башла-* фигыле белән бергә *-а* кушымчалы хәл фигыльләр урынында: Брегер рәһнамәсене вә Берлиның харитасыны ачып варылдығы кеби насыл хәрәкәт итмәк лязем килдеге хақында мәғлүмат алмаға башладық (آلمغه باشلادق) [Кәрими, 1902, б. 59]; Килдегемезең сигезенҗе көне Берлиндан китмәк хәзерлегене күрмәгә башладық (حاضرلغنى كورمكه باشلادق) [Кәрими, 1902, б. 82]; Мәғлүмдер ки, «Тәрҗеман» газетасы милләтемезең бик җаһил вә мөтәғәссиб wақытында чықмаға башлады (چيقماغه باشلادى) [Кәрими, 1908, б. 3]; Симферополь (Ақ Мәсҗед) вокзалы күренде вә инмәк ичүн әшйамызы тупламаға вә бағламаға башладық (طوپلامغه و باغلامغه باشلادق) [Кәрими, 1908, б. 48] һ.б.;

2) күчемле фигыльләр белән бергә алардан аңлашылган эшхәрәкәтнең кыек объектын күрсәтү өчен инфинитивның *-ырға* формасы урынында: Җомғадан соңра безе дәхи кәнде йанларына чәй эчмәгә (چاى ايچمگه) дәғвәт итделәр [Кәрими, 1902, б. 55]; Әлләре илә безә шурада тормаға (طورمغه) ишарәт идеп, бер тарафа кидәрәк дүрт

тәкәрлекле кечек бер әл арабасы алып килде [Кәрими, 1902, б. 64]; ...чалышмаға (چالیشمغه) йәнидән қуәт хасыйл итмәк ичүн аврупалылар берчуқ тәдбирләр вә чаралар булмышлар [Кәрими, 1908, б. 4]; Бундағы мөселманлар килмешләр, сезең илә күрешмәк ичүн, йаныңыза кермәгә (كيرمگه) мөсәғәдә истийурлар [Кәрими, 1908, б. 27];

3) хәрәкәт фигыльләре белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең башкарылу максатын ачыклау өчен инфинитивның *-ырга* формасы урынында: Озатмаға (اوزاتمغه) килән адәмләрең әл вә мәндил ишарәтләре дәхи чуға вармады, күренмәз улды [Кәрими, 1902, б. 5]; Бераздан соңра бән аның илә күрешмәгә (كورشمگه) китдем исә дә, ... [Кәрими, 1902, б. 21]; Бундан чықдықда, бер қаһвәханәйә кереп қаһвә эчәрәк бераз истирахәт итдекдән соңра Унтер ден Линден жаддәсендәге Паноптикумы сәйр итмәгә (سير ايتمكه) кердек [Кәрими, 1902, б. 82].

Төшем килешендәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрне автор башка эш-хәрәкәтнең туры объекты буларак файдалана: Парижа вардықда Эйфель қаланчасының башындан мәктүб йазмағы (مكتوب يازمغى) онытма! [Кәрими, 1902, б. 4]; ...биңләржә адәмең wақытыны буша сарыф итмәге (صرف ايتمكى) нимсәләр муафиқ ғақыл булмыйурлармыш [Кәрими, 1902, б. 84–85]; ...үзенең балалары йанында Камал хозур вә сафа илә ғөмер сөрмәге (عمر سورمگى) безем мөселман хатынлары кәнделәре тәржих идийурлар [Кәрими, 1908, б. 24]; Шунын ичүндер ки, исламийәт ирләрә дә, хатынлара да ғыйлем үгрәнмәге (علم اوكرنمكى) фарыз итмешдер [Кәрими, 1908, б. 58].

Чыгыш килешендәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдерәләр: Чүнкә отель эзләмәкдән (ايزلمكدن) йурылдық [Кәрими, 1902, б. 33]; Вә шу кеби затлар йитешеп дә, хөсне хезмәтләр илә кәнделәрене милләтә таныдырлар исә, халқымыз русҗа уқымақдан да (اوقومقدنده) қурықмаз иде [Кәрими, 1902, б. 35]; Бала туғмақдан (بالا طوغمقدن) қурқан, ... ир вә хатынлар, хәмд улсын, исламлар арасында йуқдыр [Кәрими, 1908, б. 24]; ...хөкүмәтең һәр дөрле халық арасында ғөлүм вә мәғәриф нәшер итмәкдән (نشر ايتمكدن) ғибәрәт улан ғали мақсады мәйдана киләмийурды [Кәрими, 1908, б. 83] һ.б.

Урын-вакыт килешендәге *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр башка эш-хәрәкәтнең кыек объекты буларак кулланылалар: ...кәндеңдән вә милләтеңдән көлдермәкдә (كولدرمكده) бер мәғнә дә йуқдыр [Кәрими, 1902, б. 67]; Бурада арабаҗылар илә безем Москвада улдығы кеби йарым сәғәт пазарлық итмәкдә (پازارلق ايتمكه) хаҗәт йуқ [Кәрими, 1902,

б. 68]; Қырымда берчуқ нимсә мөһаҗирләре мәүҗүд улып, игенчелек вә хайwан асрамақда (حیوان آصرامقده) йирле халықларың кяфәсендән зийадә тәрәққый итмешләрдер [Кәрими, 1908, б. 39].

Ф. Кәрими сәяхәтнамәләрендә *-мақ* кушымчалы исем фигыльләргә *ичүн* (ایچون) һәм *илә* (ایله) бәйлекләре белән кулланылу хас. *-мак ичүн* конструкциясенә язучы башка эш-хәрәкәтнең башкарылу максатын яисә сәбәбен тасвирлаганда мөрәҗәгать итә: Артық нәрсәләре тулдырып багажа вирмәк ичүн (ویرمك ایچون) бер сандық алдық [Кәрими, 1902, б. 3]; 1899 сәнәсе 15нҗе февральдә Оренбургдан хәрәкәтә қарар виреп, ақшам өсте кидән поезда утырмақ ичүн (اوطورمق ایچون) вокзала вардық [Кәрими, 1902, б. 4]; Бән дөнйайа чалышмақ ичүн (چالیشمق ایچون) килдем, ... [Кәрими, 1908, б. 15]; Моршанск вокзалында йимәк ичүн (ییمك ایچون) буфета кермеш идек [Кәрими, 1908, б. 15] һ.б.

*-мак илә* конструкциясе башка эш-хәрәкәтнең кыек объектын белдерү өчен кулланыла: Көтебханәнең моталәға салонында (одасында) йөзләрҗә иркәк вә қадын уқымақ вә йазмақ илә (اوقومق و یازمق ایله) мәшғүлдер [Кәрими, 1902, б. 43]; ...вә саирә бер тақым шәйләр алмақ илә (آلمق ایله) мәшғүл имеш [Кәрими, 1902, б. 100]; Қырым халқы шәһәрләрдә сәүдә вә тиҗарәт илә, аwылларда игенчелек, бақчаҗылық, хайван асрамақ (حیوان آصرامق), түтүн вә йөзем йитешдермәк (یتشدرمك), балықчылық вә тоз чықармақ илә (چیقارمق ایله) йәшәйурлар [Кәрими, 1908, б. 38]; Мөдәррисләр бөтен ғөмерләрене уқытмақ илә (اوقوتمق ایله) вә шәкердләр дә егермешәр, утызар сәнәлек ғөмерләрене мәдрәсәләрдә уқымақ илә (اوقومق ایله) wақыт кичерерләрде [Кәрими, 1908, б. 70].

Моннан тыш, сәяхәтнамәләрдә *-мақ* кушымчалы исем фигыльләрнең *кеби* (کبی) һәм *қәдәр* (قدر) бәйлекләре белән кулланылу очраклары да теркәлде: ...далғаларың шапыр-шапыр сахилә орылып кире китмәләрене сәйер итмәк қәдәр (سیر ایتمك قدر) ләззәтле һичбер шәй уламаз [Кәрими, 1902, б. 139]; ...вә башқа дөрле мәхсулат йитешдермәге тәҗрибә идеп бақмақ кеби (باقمق کبی) шәйләр безем халық арасында аслан тәғмим итмәмешдер [Кәрими, 1902, б. 148]; Wатаның вә мәнсе, улдығыңыз милләтең мәнфәғенә хезмәт итмәк кеби (خدمت ایتمك کبی) бүйүк вә мөқәддәс бер мақсады башыңыза қуйарақ ... [Кәрими, 1908, б. 81].

Иске татар әдәби теленең традицион үзенчәлекләреннән саналган *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең барысы өчен дә хас.

Алар билгеле бер дәрәҗәдә *-у* кушымчалы исем фигыльләрнең грамматик синонимы булып торалар. Шуның белән бергә язма чыганакларда *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр *-а* кушымчалы хәл фигыльләрне һәм *-ырға* инфинитив формасын да алыштырып киләләр.

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда, шигъри әсәрләрдә, газета текстларында һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә кулланылалар [Шамарова, 1990, с. 81; Юсупов, 2006, с. 129–130; Миннуллин, 2012, с. 208–210; Абдулхаков, 2007, с. 22]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норма, норма вариантлылыгының бер күрсәткече булып торалар.

*-мақлық* кушымчалы исем фигыльләр. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә сирәк кенә булса да госманлы төрек теле үзенчәлеге саналган *-мақлық/-мәклек* (-مق لق/-مك لك) кушымчалы исем фигыльләр дә очрый. Башқа исем фигыльләрдән аермалы буларак, алар абстракт эш-хәрәкәтне белдерәләр [Кононов 1956, с. 465].

З. Бигиев һәм Р. Фәхретдин әсәрләрендә әлеге исем фигыльләр күпчелек очракта баш килештә кулланылалар: ...безгә зарур булған эш будыр: Муса Салиховны хәбес қылмақлық (حبس قلماقلق) [Бигиев, 1887, б. 30]; Җәзасы бу иде: Муса Салиховқа ун сәнә каторжный работада хезмәт итмәклек иде (خذمت ايتمكلك ايدى) [Бигиев, 1887, б. 30]; Ғабденнәсыр әфәнденең ғаразы Муса әфәндейе қәтелдә мәғйүб иттереп, Әхмәди байның қызыны йөз мең рублә ақча илә кәләшлеккә алмақлық иде (كلش لكا آلمقلق ايدى) [Бигиев, 1887, б. 48–49]; ...Хәдичә туташның мәразында ғыйлаҗ бу иде: Самар губернасында қырғыз қымызы эчмәклек (اچمكلك) [Бигиев, 1887, б. 53]; Бәнем қалмақлықым (قالمقلقم) лязем, йуқса бер кемсәнәгә олуғ зарар улачақ дидем [Фәхретдин, 1899, б. 38–39]; ...киләчәк көндә кәнделәренә ғаилә әхwәле әманәт иделенәчәк әғзәләре мәзкүр мөбах әйләнчәләре сәфаһәт ханәләрдән вә харам йуллар үзәренә эзләмәйә мәҗбүр итмәклегемез (مجبور ايمكلكمز) лайык бер эш дәгелдер, зан идәрем [Фәхретдин, 1903, б. 26].

Ф. Кәрими сәяхәтнамәләрендә *-мақлық* кушымчалы исем фигыльләр нигездә юнәлеш килешендә очрыйлар: ...һич оныдылмайаҗақ дәрәҗәдә сафалы вә файдалы бер сәяхәт итмәклегемә (سياحت ايتمكلگمه) вә сәйәхәтең нәтиҗәсе уларақ бу рисаләйе йазмақлығыма (يازمقلغمه) сәбәб

улан ғалиҗәнаб Шакир әфәндейә... [Кәрими, 1902, б. 191]; Хәмитҗан әфәнде Арабов нам бер зат илә икемезең тәбрик ичүн «Тәрҗеманың» йегерме сәнәлек доғасы мәҗлесенә Бағчасарайа вармақлығымыза (وارماقلغمزه) қарар вирелде [Кәрими, 1908, б. 3]; ...арз итмәк ичүн беркач сүз сөйләмәклегемезә (سويله مكلكمزه) мөсәғәдәңезе риҗа идәрем [Кәрими, 1908, б. 79].

Шуның белән бергә чыганакларда аларның төшем килешендә (а) һәм *илә* (ايله), *ичүн* (ايچون) бәйлекләре (ә) белән бергә кулланылу очраклары да теркәлде:

а) Ләкин Ғайшә ханым рус лисаны илә тәкәллем қылмақлықны (تكلم قلمق لقنى) белмәк дәгел, бәлки русча йазмақ-уқымақ да беләдер иде [Бигиев, 1887, б. 66]; Вә зыйарәт идәр ичүн бу қәдәр мөсафәләр вә бу қәдәр масрафлар тотып йөрмәклегеңне (يورمكلكڭ نى) ғыйбәдәт дийә кемдән ишетдең?.. [Фәхретдин, 1899, б. 49]; Әһали дә бәнем урада қалмақлығымы (قالمقلغمى) чуқ эстәмешләр иде, ... [Кәрими, 1908, б. 105];

ә) ...кичәләрдә рөэйәмдә сез ғазизләремезне күрмәклегем илә (كورمك لكم ايله) күңелем хушланыр [Бигиев, 1887, б. 35]; ...әгәр эстәр исәңез, сезең дәхи урайа вармақлығыңыз ичүн (وارمقلغكز ايچون) җәмғыйәтең рәисендән мөсәғәдә алып, ... [Кәрими, 1902, б. 116].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка, госманлы теле өчен хас булган *-маклык* кушымчалы исем фигыльләр шигъри әсәрләрдә генә кулланылалар [Юсупов, 2006, с. 130]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алмыйлар һәм XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби теле өчен хас булган функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*Инфитинив.* Хәзерге татар тел белемендә инфинитив исеме астында эш-хәрәкәтне субъектка һәм зат, сан, заман категорияләренә бәйсез рәвештә атап килә торган затланышсыз фигыль формасы карала. Морфологик планда ул барлыкта-юклыкта килә һәм юнәлеш кушымчаларын ала.

Бүгенге көндә татар теле диалектларында инфинитивның сигез формасы кулланыла [Юсупов, 2004, с. 190–240]. Әдәби телдә аның *-ырга/-ергә, -рга* кушымчасы ярдәмендә ясалган формасы норма буларак аерып чыгарыла [Татарская грамматика, 1997, с. 230–232; Тумашева, 1978, б. 160–161; Хисамова, 2006, б. 269–270].

Хәзерге татар әдәби телендә норма буларак қабул ителгән *-ырға* кушымчалы инфинитив формасындагы фигыльләрнең XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби телендә дә төрле дәрәҗәдә кулланылуы күзәтелә. Шуның белән бергә, татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә аны күпчелек очракта *-ма* һәм *-мақ* кушымчалы исем фигыльләр алыштырып килә.

М. Акьегетнең «Хисаметдин менла» романында *-ырға* кушымчалы инфинитив формасындагы фигыльләр сирәк очрый. Автор аны персонажлар сөйләмендә генә һәм, нигездә, хәрәкәт фигыльләре белән бергә куллана. Бу очракта ул башка эш-хәрәкәтнең максатын белдереп килә:

...

– Менла син улымның хәлене белергә (حالنى بيلوركا) күпдән килмисең.

– Хәзердә хәл белергә (حال بيلوركا) килдем, абыстай [Акъегет, 1886, б. 48];

...

– Сән қайда болай бик иртә барасың тутай? – сурды йәшрәк қадын.

– Икмәкләремне пичкә қуйғанда көрәгем йарылды, көрәк сорарға (صورارغه) барамын, – җаwабланды қарт қадын [Акъегет, 1886, б. 51];

...

– Ирем дүнке көн ахшамдан байға туй хәзерләшергә (توى حاضرلشرغه) китде, – диде йәшрәк қадын [Акъегет, 1886, б. 51].

Шуның белән бергә әсәрдә *-ырға* кушымчалы инфинитивның *эстә-* фигыле белән бергә кулланылу очрагы да теркәлде:

...

– Инде Хәнифә синең уғлыңа насыйб булмады күрәсең. Бу көн анда ниқах уқырлар диде йәшрәк қадын.

– Ах балақай, күңел йөгерек дә ходадан нәдер бойырық, бәнем Хисаметдинем алырға (الورغه) пәк эстәде, әмма нә қылырсың [Акъегет, 1886, б. 51].

З. Бигиев романнарында *-ырға* кушымчалы инфинитив формасындагы фигыльләр автор сөйләмендә дә, персонажлар сөйләмендә дә очрый. Биредә ул, нигездә, башка фигыльләр һәм модаль сүзләр белән бергә түбәндәге очракларда кулланыла:

1) күчемле фигыльләр белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең кыек объектын күрсәткәндә: Җәмғ улмыш җәмәғәт номер

эченә керергә (کرورکا) нә қәдәр қасд итделәр исә дә, номергә керүдән мәнғы қылындылар [Бигиев, 1887, б. 4]; Әфәндем, сезне бер адәм күрергә (کوررکا) эстәйур, кертергә рөхсәт бармы? [Бигиев, 1887, б. 10]; Бераз сабыр қылыңыз, ат йигәргә (آط یکرکا) қуштырайым, ат илә қайтырсыз [Бигиев, 1887, б. 13]; ...ләкин мән үз тарафымдан бу шәкердкә дамелла Ғабделкәрим хәзрәт мәдрәсәсенә керергә (کرورکا) мәслихәт қылыр идем [Бигиев, 1890, б. 10]; Маһруй Йағқубдан бөйләчә салқын сүзләр ишедергә (ایشدرکا) зан қылмаған иде [Бигиев, 1890, б. 18]; ...ләкин хәзердә кеше қапысына да ташларға (تاشلارغه) бик хәвеф қыламын [Бигиев, 1890, б. 20] һ.б.;

2) хәрәкәт фигыльләре белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең башкарылу максаты турында язганда: Биш-алты дәқиқа кәчдекдән соңра, Муса әфәнде йирендән торып тәһарәтләнергә (طهارتلنورکا) чықды [Бигиев, 1887, б. 14]; Муса әфәнденең хәлене белергә (حالونی بلورکا) һәр көн килийурлар [Бигиев, 1887, б. 35]; Мән өйдән киткәндә дә эчәргә (ایچرکا) китеп қалды [Бигиев, 1890, б. 47]; Анлар өйгә ашарға (آشارغه) килгәч, хуҗамыз анларны профессор Зақталовның өйене буйарға (بویارغه) йибәрде ... [Бигиев, 1890, б. 71];

3) *кирәк* (کرك) модаль сүзе белән бергә үтәлеше зарур булган эш-хәрәкәт турында сөйләгәндә: Намаз wақыты йитде, тәһарәтләнергә кирәк (طهارتلنورکا کارك) [Бигиев, 1887, б. 14]; Қайын әткәйеңезгә хәбәр итәргә кирәк (خبر ایترکا کرك) [Бигиев, 1887, б. 16]; Ничек булса да дәфен қылырға кирәк (دفن قیلورغه کرك) [Бигиев, 1890, б. 57]; Менә мәнем үзем тора торған бүлмәләрдә тәрәзәләрне буйарға кирәк (بویارغه کرك) ... [Бигиев, 1890, б. 71];

4) *мөмкин* (ممکن) модаль сүзе белән бергә мөмкинлек мәгънә төсмере белән баетылган эш-хәрәкәтне белдергәндә: Әгәр дә эстәсәң, мән balaңы воспитательный өйгә дә итәрмен, йәки башқа йиргә дә ташларға мөмкин (تلشلاغه ممکین) [Бигиев, 1890, б. 19]; Сәнең хуҗаң малдар кеше, сездән күп алырға да мөмкин (آلورغه ده ممکین), ... [Бигиев, 1890, б. 21].

Шуның белән бергә «Гөнаһе кәбаир» романында *-ырға* кушымчалы инфинитив формасындагы фигыльләрнең мөстәкыйль кулланылыш очраклары да теркәлде. Әлеге алымга автор персонажларның эчке халәтен тасвирлаганда мөрәҗәгать итә: ...Мәмәтнең дә кәсебләре шимди начар улдығы ичүн, бер көн ач вә бер көн туқ улып, хезмәтсез, ағырлық илә көн кәчерийурлар иде. «Қайдан икән ақча алырға (آقچه آاورغه)? Ничек икән бай булырға (بای بولورغه)?» – дийү ачлық хәс-

рәтендә улып, Мәмәт илә Ғабделғафур сөйләшеп утырырларкән, номерә ишеге ачылып, мәғлүмеңез Ибраһим Ғалийев керде [Бигиев, 1890, б. 52].

З. Бигиевнең «Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр)» сәяхәтнамәсе өчен *-ырға* кушымчалы инфинитив формасындагы фигыльләрнең кулланылышы хас түгел.

Р. Фәхретдин романнарында *-ырға* кушымчалы инфинитив формасындагы фигыльләр шулай ук автор сөйләмендә дә, персонажлар сөйләмендә дә очрый. Чыганакларда аларның мөстәкыйль рәвештә кулланылыш очраклары теркәлмәде. Биредә алар башка фигыльләр һәм модаль сүзләр белән бергә түбәндәге максатларда кулланылалар:

1) *башла-* фигыле белән бергә *-а* кушымчалы хәл фигыльләр урынында: Йаурупа шәһәрләренә күрше улдықлары сәбәбдән мода динелгән зарарлы хасталық бунлар арасында күрелергә башламышдыр (كورلورگا باشلامشدر) [Фәхретдин, 1899, б. 4]; Бу сәғәтдә иғтиқад вә фикеремнең хата идегене гүзәл аңлап, үз-үземә шелтә идәргә вә тәәссеф қылырға башладым (شلته ايدلاگا و تأسف قيلورغه باشلادم) ... [Фәхретдин, 1899, б. 20]; Әхмәд ағай бәнем йанымарақ килеп, ачы даwыш илә бөйлә сөйләргә башлады (سويلركه باشلادى) [Фәхретдин, 1903, б. 80]; Бунда шул эш булмазса йахшы иде, шөбһәләнеп, көтеп торырға башладым (كوتوب طوررغه باشلادم) [Фәхретдин, 1903, б. 84];

2) күчемле фигыльләр белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең кыек объектын күрсәтү өчен: Вәғәзләре илә ғәмәл идәргә (عمل ايدرگا) ғәһедләр итдем [Фәхретдин, 1899, б. 6]; Бунлар арасына төшәргә (توشرگا) рус вә нимсәләрнең йөрәкләре, әрмән вә йәһүдиләрнең ғәйрәтләре йитмәз иде [Фәхретдин, 1899, б. 11]; Әтрафында улан меллалар һәр нә қәдәр Ғайшә абыстайда күңелләре улмақда исә дә, бөйлә фикерләрне аңладырға (آڭلادرغه) җәсарәт идә алмазлар иде [Фәхретдин, 1903, б. 42]; Балаларының намаз уқып йөргәнене күргән соң, ата вә аналары һәм уқырға (اوقورغه) ғәдәтләнгәнләр [Фәхретдин, 1903, б. 82];

3) хәрәкәт фигыльләре белән бергә алардан аңлашылган эш-хәрәкәтнең башкарылу максаты турында язганда: Мәгәр дә конторға вардығым илә бер груһ халық бәне қаршы алып, озадырға (اوزادرغه) килдекләрене вә бәнем ичүн билет алып урын хәзерләдекләрене бәйан итделәр [Фәхретдин, 1899, б. 9]; Йуқса, дәрес ишедергә (درس ايشدركه) килдеңезме? [Фәхретдин, 1903, б. 84]. Йаңлышмаз исәм, ибдәшләрең илә Қазан шәһәренә уқырға (اوقورغه) кәтдегең wақытда исәнләшдегемез сәғәтдә син вирдең!... [Фәхретдин, 1903, б. 130];

4) *тийешле* (تیوشلی), *тийеш* (تیوش) модаль сүзләре белән бергә башкарылырга тиеш булган эш-хәрәкәт турында язганда: Мөселман хатынының баласы йә мәктәбдә тәхсилдә, йәки йырақ шәһәрләрдә кәсебдә улырға тийешледер (کسبده اولورغه تیوشلیدر) [Фәхретдин, 1899, б. 5]; Йулбашчыларымыз исә ислам ғилеме илә замана әхwәлене фәлсәфәсе илә белгән затлар улырға тийешледер (اولورغه تیوشلیدر) [Фәхретдин, 1899, б. 10]; Бунсы мантыйққа маһир булырға тийеш (ماهر بولورغه تیوش) [Фәхретдин, 1903, б. 27]; Ләкин аның йазуы да үзенә бер төрле булырға тийеш (بولورغه تیوش), ... [Фәхретдин, 1903, б. 81];

5) *кирәк* (کرک) модаль сүзе белән бергә үтәлеше зарур булган эш-хәрәкәт турында сөйләгәндә: Қазандан берәр йөзне алдырып қуйарға кирәк (آلدروب قويارغه کرک)! [Фәхретдин, 1903, б. 31]; Бундан башқа йорт хезмәтләре күп, сабан сөрүчеләргә икмәк пешерергә кирәк (ایکمك پشررکه کرک), ... [Фәхретдин, 1903, б. 106]; Кич қайтуларына ашарға хәзерләргә кирәк (آشارغه حاضورلرکه کرک) [Фәхретдин, 1903, б. 106].

Ф. Кәрими сәяхәтнамәләре өчен *-ырға* кушымчалы инфинитив формасындагы фигыльләр хас түгел. Биредә аларның бары тик аерым кулланылыш очраклары гына теркәлде: ...Йосыф китабы илә Бақырған китабыны көйләп уқырға (کويلاب اوقورغه) белүҗе остазбикәләремез йуқ дәгелдер [Кәрими, 1902, б. 144]; Ә-ә-ә, әллә анда қазнаға ат қуйарға (آت قويارغه) барасызмы? [Кәрими, 1908, б. 13].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-ырға* кушымчалы инфинитив формасындагы фигыльләр чәчмә характердагы әдәби әсәрләрдә генә урын алалар. Сәяхәтнамәләрдә алар иске татар әдәби теленең традицион үзенчәлекләреннән саналган *-мак* һәм госманлы төрек теле өчен хас булган *-ма* кушымчалы исем фигыльләр белән алыштырылалар. *-мак* кушымчалы исем фигыльләрнең инфинитив мәгънәсендә кулланылуы ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннар, шигъри әсәрләр, газета текстлары һәм дини-фәлсәфи хезмәтләр өчен дә хас [Шамарова, 1990, с. 80; Юсупов, 2006, с. 137; Миннуллин, 2012, с. 208–210; Абдулхаков, 2007, с. 22]. Шуның белән бергә ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда һәм газета текстларында *-ырға* кушымчалы инфинитив формасындагы фигыльләр дә кулланылалар [Шамарова, 1990, с. 80; Миннуллин, 2012, с. 206–208]. Шигъри әсәрләрдә һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә исә аларның бары тик аерым кулланылыш очраклары гына теркәлгән [Юсупов, 2006, с. 138; Абдулхаков, 2007, с. 23]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, *-ырға* кушымчалы инфинитив формасындагы фигыльләр бу чорда иске татар язма әдәби

теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да тиешле дәрәҗәдә урын алмыйлар һәм XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби теле өчен хас булган функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар. Бу аларның әдәби кулланылышка яңа керә башлавы һәм мәгънәләренең башка затланышсыз фигыльләр тарафыннан белдерелүе белән аңлатыла.

*Кыскача нәтиҗәләр.* XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында иҗат ителгән язма чыганаклардан күренгәнчә, иске татар әдәби теленең табигатен, аның үсеш закончалыкларын билгеләгән язма традицияләр, норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык бу чорда әдәби кулланылышта булган затланышсыз фигыль формаларында төрле дәрәҗәдә чагылыш таба. Аерым алганда, әлеге өлкәдә әдәби норма һәм норма вариантлылыгының күрсәткечләре буларак *-р, -ачаӄ (-аҗаӄ), -ған, -ан, -мыш, -дыӄ* кушымчалы сыйфат фигыльләрне; *-ып* кушымчалы хәл фигыльләрне; *-у, -маӄ* кушымчалы исем фигыльләрне аерып чыгарырга мөмкин. Әлеге затланышсыз фигыль формалары үзләренең барлык мәгънәләрендә бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар. Шуның белән бергә *-учы (-уҗы)* кушымчалы һәм *-а торған* сыйфат фигыльләр, *-а, -ғач, -араӄ, -ынча, -дыӄча, -маздан, -мадан* кушымчалы хәл фигыльләр, *-ма, -маӄлыӄ* кушымчалы исем фигыльләр һәм *-ырға* кушымчалы инфинитив, барлык язма чыганакларда да урын алмаган хәлдә, функциональ-стилистик вариантлылык күрсәткечләре булып торалар. Бу аларның әдәби кулланылышка яңа керә башлавы һәм мәгънәләренең күпчелек очракта башка затланышсыз фигыльләр ярдәмендә белдерелүе белән аңлатыла.

# ЙОМГАК

«Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). II том. Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлеге: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык» дип тәкъдим ителә торган бу хезмәт күрсәтелгән дәвердә төрле жанр-стильләрдә иҗат ителгән, шәрехләнгән, тәрҗемә кылынган язма истәлекләрдә, әдәби телнең морфология тармагында өйрәнелә торган мөстәкыйль сүз төркемнәренең аерым авторларның әсәрләрендә ничек итеп кулланылуын анализлауга багышлана. «Татар грамматикасы»нда мөстәкыйль сүз төркемнәре сигез дип [Татар грамматикасы, 2002, б. 12], «Татар морфологиясе»ндә алар җиде дип бирелә, ягъни хәбәрлек сүзләр модаль сүзләр белән бергә карала [Хисамова, 2006, б. 58]. Бу очракта, күрсәтелә торган дәвердә иҗат ителгән текстларда исем, сыйфат, затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр, рәвеш, сан, алмашлык дип атала торган мөстәкыйль сүз төркемнәренә хас булган грамматик мәгънә һәм аны тәкъбир итә торган форманың аерым автор тарафынан ничек итеп файдалануы өйрәнелә, хронологик тәртипкә салынган әлеге нигездә әдәби тел тарихы күзаллана. Мөстәкыйль сүз төркеменә мөнәсәбәтле ияртемнәр һәм хәбәрлек сүзләр, шулай ук ярдәмлек сүз төркеме дип берләшә торган модаль һәм бәйләгеч сүзләрне әдәби тел тарихы максатыннан карап тикшерү эше алдагы бурычыбыз булып кала.

Күрсәтелгән дәвердәге язма истәлекләрне татар әдәби теле тарихының бер буыны буларак тикшергәндә, шул әсәр телендә, беренчедән, ерак гасырлардан килә торган язма традициянең дәвам ителешенә, икенчедән, җирле төбәктәге сөйләмә тел, диалекталь үзенчәлекләр белән ни дәрәҗәдә баетыла баруына игътибар ителә.

Нәтиҗәдә, традиция булып килә торган норманың вариантлылыкларын билгеләргә мөмкин була.

Әдәби язма телне тикшерү җанлы сөйләмә телне анализлаудан нәкъ шушы нигездә аерымлана. Әлеге проблемага, ягъни әдәби телнең билге-шартларына караган теоретик-нәзари мәсьәләләр, хосусый метод-ысуллар, методология, «Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык» дип аталган I томның керешендә [Татар әдәби теле..., 2015, б. 8–232] тәфсилләп аңлатылганга күрә, II томның керешендә, нигездә, хәзерге татар морфология тармагына мөнәсәбәтле гамәли, аерым алганда, сүз төркемнәренең атамасында, махсус терминлаштырылып, аларның табигате һәм вазифасының объектив чагылу мәсьәләсенә игътибар ителде, аерым гомумтеоретик нигезләмәләргә, сүз җаен саклау максатыннан, кыскача тукталып үтелде.

Әдәби тел тарихын өйрәнү эше дәверләр, гасырлар буена язылып килә торган әдәби истәлекләрнең һәр аерым чыганагында кулланыла торган тел берәмлекләрен җентекләп тикшерүгә һәм аларны ныклы системага салып аңлатуга нигезләнә, әдәби тел тарихын язуның төп принцибы булып санала. «Татар әдәби теле тарихы»ның I томын язу барышында, тикшерүләрдән күренгәнчә, иске татар телендә, хәзерге әдәби телдән аермалы буларак, авторның кайсы укучыны (адресатны) күздә тотып, нәрсә турында бәян итүенә, шулай ук әдәби телнең кайсы стилендә язуына карап, тел берәмлекләрен сайлап алып кулланырлык байлык-запаска ия булуы ачык күренде. Шуңа күрә, һәр аерым язма истәлекне өйрәнү барышында авторның теге яки бу тел берәмлекләрен ни өчен сайлавына, бу юнәлештә язма традициянең ни дәрәҗәдә саклануына, яисә сакланмавына һәм сөйләмә/диалект телендәге сүз, сүзформаларның ничек әдәбиләштерелүенә игътибар итү мәсьәләсе күз уңында тотылды. Шул ук вакытта, әлеге сайланып алына торган тел берәмлекләренең аерым автор тарафыннан ничек итеп файдаланылуын (ягъни бер мәртәбә кулланыламы ул, яисә берничә мәртәбә кабатланамы), бер берәмлекнең икенчесе белән ни өчен алмаштырылуын һ.б.ны билгеләргә, нәтиҗәдә, авторның язганнарына карата үзенчәлекле мөнәсәбәтен ачыкларга мөмкинлек бирелә. Шулай итеп, текст эчтәлегендәге сүз, сүзформа, сүзтезмәләрнең күп төрле вазифа башкарып кулланылуы ачыклана. Димәк, аерым әсәрнең теле тикшерелгәндә тел берәмлегенең, язма сөйләм (текст) эченә килеп кергәч, катлаулы экстралингвистик функциональ мөмкинлеген ачып күрсәтү

зарурлыгы күренә. Бу төрдәге эшчәнлек лингвистиканың барлау-теркәү дигән төп метод-ысулына нигезләнеп башкарыла.

Аңлашылганча, текст эчтәлегендә күп кырлы вазифа үти алырлык яшәеш алган тел берәмлегенең, функциональ колачының ни дәрәҗәдә булуын күзаллау өчен, аның, язма сөйләмгә (текстка) килеп кергәнче үк, үзенә генә хас булган асыл табигатен тәгәл белергә кирәк була. Һәр тел берәмлегенең фонетика, морфемика, морфология, лексика, сүзьясалыш, синтаксис кебек хосусый тармакларындагы тәфсилләп анализланган структур-субстанциональ төзелешенең асылына төшенергә, яхшылап зиһенгә алырга кирәк була.

«Татар әдәби теле тарихы»ның I томында, XIII гасырдан – XX йөз башына кадәр эзлекле рәвештә хәрәкәттә булып дәвам итә торган әдәби телнең фонетика һәм графика тармакларын тикшерү эшн, татар теле авазларының үзләренә хас булган табигатен барлаудан, ягъни калынлыкта-нечкәлектә аерымлануы, сингармонизм күренешенең саклануы-сакланмавы һ.б. үзенчәлеген күзаллаудан башланды. Аннан соң, хәзерге вакытта кирилл хәрефләре белән языла торган татар авазларының иске татар телендә гарәп графемасы белән ничек итеп күрсәтелүен анализлауга керештек. Әлегә кадәр тикшерелә торган хезмәтләрдән аермалы буларак, анализны гарәп графемасының кайсы авазны белдерүен барлаудан түгел, татар авазын күрсәтә торган кирилл хәрефләрен алгы планга куеп, гарәп графемасы белән ничек итеп язылышын билгеләүдән башларга кирәк булды. Шушы нигездә генә язма традициянең ничек баруын күзәтү мөмкинлеге күренде. Төрки-татар авазларының, гарәп теле кагыйдәсе таләбе белән, сүз башы, сүз уртасы, сүз ахырына туры китерелеп язылышы билгеләнгәндә, традицион норма һәм аның вариантларын төгәлрәк күзәтергә, бер уңайдан табигате белән аерымлана торган төрки-татар сүзләренең һәм гарәп-фарсы алынмаларының үзара мөнәсәбәтен аңларга мөмкин булды. Алынмаларның катгый рәвештә үз чыганак теле кагыйдәсенә буйсынып язылуы, димәк, шул дәрәҗәдә норманың саклануы билгеле булганга, төп игътибарны иске имля тәртибендә бирелә торган төрки-татар сүзләренең язылышына игътибар итәргә туры килде. Әлеге мәсьәләләр берсе икенчесенә табигате белән туры килми торган телләрне тикшерүдә төп ысул булып санала торган чагыштырма-типологик методка нигезләнеп хәл ителде.

«Татар әдәби теле тарихы»ның II томында гасырлар буена иске татар телендә язылган әсәрләрнең морфология тармагына караган

мәсьәләләре тикшерелгәндә, һәр сүз төркеменә хас булган грамматик мәгънә һәм грамматик формаларның ничек итеп файдаланылуын өйрәнүне дә, фонетика тармагында, әдәби тел тарихын анализлау өчен кулай дип табылган әлеге принципка таянып, ягъни өйрәнелә торган күренешне, аерым текстта кулланыла торган тел берәмлекләренең үзенчәлеген билгеле ныклы җирлектә ачыграк күрү максатыннан, хәзерге татар телендәге торышын истә тотып, аңа нигезләнеп алып барылды.

Бу хезмәттә лексик-семантик яктан төрле булган сүзләрнең, гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә лексик-грамматик яктан гомумиләшеп барлыкка килә торган сүз төркемнәренең һәр сүз төркеменең үзенә хас булган грамматик мәгънә һәм грамматик форма берлегенең катлаулы табигатен аңлап эш итү максаты куелды. Әлеге максатка ирешү юнәлешендә, беренчедән, грамматик категория, грамматик мәгънә һәм грамматик форма кебек төшенчәләрнең хәзерге татар теле белемендә ничек итеп аңлатылуын, икенчедән, һәр аерым сүз төркеме тикшерелгәндә, теоретик фикерләрнең гамәли яктан ничек файдаланылуын белергә кирәк булды. Шул ук вакытта, әлеге сайланып алына торган тел берәмлекләренең аерым автор тарафыннан ничек итеп файдаланылуын (ягъни бер мәртәбә кулланыламы, яисә берничә мәртәбә кабатланамы), бер берәмлекнең икенчесе белән ни өчен алмаштырылуын һ.б.ны билгеләргә, нәтиҗәдә, авторның язганнарына карата үзенчәлекле мөнәсәбәтен ачыкларга мөмкинлек бирелә. Шулай итеп, текст эчтәлегендәге сүз, сүзформа, сүзтезмәләрнең күптөрле вазифа башкарып кулланылуы ачыклана. Димәк, аерым әсәрнең теле тикшерелгәндә, тел берәмлегенең, язма сөйләм (текст) эченә килеп кергәч, катлаулы экстралингвистик функциональ мөмкинлеген ачып күрсәтү зарурлыгы күренә.

Телнең грамматик төзелешен барлыкка китерә торган морфемика, морфонология, сүзъясалышы, морфология һәм синтаксис тармаклары тикшерелеп язылган хезмәтләрдән күренгәнчә, грамматик категория дигән күренешнең хәзерге татар теле гыйлемендә берсе икенчесенә бәйле булган ике аспектта: а) гомуми теоретик нигездә күзаллануы һәм ә) аерым сүз төркемнәренә хас булган үзенчәлек буларак өйрәнелүе мәгълүм. Гомуми теоретик планда күзаллана дигәндә, рус телендә дөнья күргән «Татарская грамматика» хезмәтендә [Татарская грамматика, 1993, с. 130–141] һәм татар телендәге басмада «Грамматиканың төп төшенчәләре (морфемика, морфонология, сүзьясалышы,

морфология һәм синтаксиска башлангыч кереш» [Татар грамматикасы, 1998, б. 152–161] дигән тикшеренүләрдәге мәгълүматны истә тотарга кирәк булды. Бу юнәлештәге фикерләрнең, асылда, «Гомуми тел белеме»ндә бирелә торган тәгълиматка туры килүе, ягъни объектив фәнни булуы ачыкланды. Шул нигездә тикшерелә торган сүз төркемнәренә грамматик категория таләбенә туры китерелеп билгеләмә бирелде, сүз төркемнәрен тикшерүнең төп принцибына игътибар юнәлтелде.

Шуның белән бергә, XIII гасыр – XX йөз башы татар әдәби теленә караган истәлекләрдә һәр сүз төркеме тикшерелә башлаганда, аның һәр категориясенең хәзерге әдәби телдәге, кирәк урында диалекталь сөйләшләрендәге структур-субстанциональ халәте күзалланды. Һәр чорга караган язма әсәрләрдә кулланыла торган һәр сүз төркеменең һәр категориясе аерып алып тикшерелде, күпчелек очракта, төп текстта билдерелгәнчә, гарәп телендә язылган мисалы белән күрсәтелеп, хәзерге татар телендәге варианты белән ачыкланды. Кыскача нәтиҗә ясалганда, кирәк урында, статистик мәгълүмат бирелә барды. Күрсәтелгән чорларда иҗат ителгән, басылган, шәрехләнгән язма әсәрләрдә кулланыла торган сүз төркемнәренең, асылда, хәзерге татар теле кысасында булуы, әмма һәр дәвердә грамматик категорияләрнең билгеле бер вариантлары белән файдаланылуы, әлеге үзенчәлекләрнең алга таба традиция буларак үстерелә баруы мәгълүм булды.

XIII гасыр Идел буе Болгар дәүләте чорында иҗат ителгән истәлекләр теле, графо-орфографик тармагындагы кебек үк, һәр сүз төркеменең категорияләре кулланылышыннан аңлашылганча, күп гасырлык борынгы төрки, угыз-карахани-уйгыр әдәби телләренә барып тоташа, шул рәвешле традицион уртаклыклар дәвам итәлә. XIV гасыр Алтын Урда дәүләтендә иҗат ителгән әсәрләр телендә, карахани-уйгыр әдәби тел күрсәткечләре белән бергә, кыпчак тел күренешләренең шактый иркен кулланылулары күзәтелә. Тулаем төрки дөньяның рухани һәм дөньяви мәдәнияте мирасы булып санала торган әсәрләр, яңа шартларда региональ сөйләмә формалар белән кушылган, ягъни болгар, кыпчак телләренә нигезләнгән, угыз тел үзенчәлекләрен үзенә берләштергән тел белән языла, татар язма әдәби теленең әлгәргесе булган Идел буе төрки әдәби теле формалаша.XV – XVI гасырлар Казан ханлыгында иҗат ителгән әсәрләрдә, асылда, Болгар чоры, Алтын Урда әдәби язма традициянең дәвам ителгән хәлдә, төрле әсәрдә төрле дәрәҗәдә, болгар-татар халкының өч төрле этник төркеменең сөйләм үзенчәлекләре дә урын ала. XVI гасырның икенче яртысыннан, XVII,

XVIII гасырларда иске татар теле Россия империясенең икенче функциональ дәүләт теле буларак файдаланыла, рәсми эш кәгазьләре стиле активлаша. Поэзия һәм проза әсәрләрендә, адресатка карап, төрки телнең абруйлы һәм халыкчан вариантлары тагын да сизелерлек аерымлана. Бу хәлләрнең барысы да әдәби телнең морфологиясендә, грамматик мәгънә һәм формаларының кулланылышында чагылыш таба.

XIX гасыр – XX гасыр башында иҗат ителгән әсәрләрнең теле тикшерелә торган бүлектә, а)чыганакларның күплеге, аларны поэзия һәм проза дип аерып карарга мөмкин булуы, ә) адресатның кем булуына карап, әлеге әсәрләрдә абруйлы төрки һәм халыкчан төрки телнең тәэсире чагылышы, б) сәнгатьле чәчмә әсәрләрнең 1, 2, 3 төрләр дип бүлеп карала торган хикәяләү стильләре белән иҗат ителүе, в) барлык функциональ стильләрнең кулланылышта булуы, аларның әдәби телгә үз таләпләрен белдерүе кебек лингвистик һәм экстралингвистик факторларның бергә үрелүе нәтиҗәсендә, әдәби тел мәсьәләләрен өйрәнүгә киңрәк урын бирелде. Әдәби тел, төрле сөйләм типларының (стильләрнең) үзләренә хас булган таләпләренә җавап бирү йөзеннән, шул стильләрдә хосусый кулланылуы зарур булган үзенчәлекләргә ия булып, функциональ-стилистик вариантлылык хасил итеп хәрәкәттә булуы, шул ук вакытта, иҗтимагый тормышта бара торган сәяси хәлләрнең тәэсире белән социаль-структур вариантлылыкка ия була алуы күренде. Фонетика тармагында әлеге мөмкинлекләр графо-орфографик тәртипкә салынып хәл кылынса, морфология тармагында грамматик категорияләр барлыкка китерә торган грамматик мәгънә һәм грамматик формаларның табигате һәм вазифасында чагылыш таба. Сүз җаена туры китереп, шуны да әйтеп үтәргә кирәк, язма истәлекләрнең морфологиясе өйрәнелгәндә, төрки-татар һәм гарәп-фарсы алынмаларын, фонетика тармагындагы кебек, берсен икенчесеннән кырт кисеп аерып карарга мөмкин булмавы күренә. Дөрес, исем сүз төркеменә хас булган сан һәм тартым категорияләрендә аларны аерып алып карарга җирлек булса да, бөтенләй үк аерылмавы күренә: гарәп вә фарсы алынмалары, чыганак телләрендәгечә, берлек, икелек, күплек санда кулланылсалар да, төрки-татарның *-лар* кушымчасы белән дә языла, барлык килешләрнең кушымчаларын алып файдаланыла, фигыльләрдә гарәп-фарсы алынмалары төрки-татар теленә хас булган ярдәмлекләр белән тезмә фигыльләр хасил итә һ.б. Язма традициянең ни рәвешле дәвам ителешен ачыграк күз алдында тоту максатыннан, хәзерге әдәби телдә кабул ителгән тәртип-низам сакланган

хәлдә, тикшерелә торган тексттагы һәр сүз төркеменең һәр категориясенә хас булган үзенчәлекләрне мөмкин булган дәрәҗәдә тәфсилләргә тырышылды. Бу юнәлеш бер үк язма телнең төрле этабындагы үсеш-үзгәрешен күзаллау өчен уңай дип табылган чагыштырма-тарихи методка нигезләнеп алып барылды.

Әлеге мәсьәләнең, ягъни язма истәлекләрне әдәби телнең морфология тармагы таләп итә торган югарылыкта өйрәнү эшенең нәтиҗәсен күрү өчен, телнең фонетикасы (графо-орфографиясе) һәм синтаксисы белән бәйләнешенә игътибар итәргә кирәк булуы мәгълүм. Һәр сүз төркеменең һәр аерым категориясе анализланганда бу бәйләнеш-мөнәсәбәтнең эзлеклелеге күз уңында тотылды, ныклы системага салып тикшерелде, һәр бүлекчәдән соң кыскача нәтиҗә ясап барылды. Язма әдәби телнең морфология өлкәсендә традиция булып килә торган әдәби норма һәм аңа хас булган вариантлылык, аерым сүз төркемнәренә хас булып, аларны яшәтә торган грамматик категорияләрне барлыкка китерә торган грамматик мәгънә һәм грамматик формаларда ничек чагылыш табуы мәсьәләсенә караган барлык гасырлардагы үзенчәлекләр берләштерелеп, гомуми йомгакта урын алды.

Исем сүз төркемендә, грамматик мәгънәсе ягыннан, предметларның бер яки бердән артыклыгын махсус формаларда белдерә торган сан категориясендә, берлек һәм билгесез күплек мәгънәсе ике телгә хас булган әдәби норма күрсәткечләре белән тәгъбир ителә: а) төрки-татар теле өчен әдәби булганы: берлек саны – нуль форма, күплек саны – *-лар* кушымчасы белән белдерелә, ә) гарәп-фарсы теле өчен әдәби булганы: берлек саны – нуль форма, икелек саны *-ан, -әйен,* «бөтен» күплек *-ат, -ун, -ин, -ийат (-ият)* аффикслары белән, «ватык» күплек саны кушымчасыз, сүзне «ватып», аның сузыкларын алмаштыру ярдәмендә ясала.

Әлеге ике әдәби норманың түбәндәге норма вариантлары күзәтелә: 1) графо-орфографиягә нигезләнгәне: *-лар* аффиксының әлиф белән һәм әлифсез языла алуы; 2) морфологиягә нигезләнгәне: а) исемнең төрле семантик төркемчәләренә (ялгызлык, конкрет, абстракт, җыйма, әйбер-матдә мәгънәсенә) караган сүзләрнең берлек формасында да, күплек формасында да кулланылуы; ә) *-ат, -ит* күрсәткечле һәм сынык күплектәге гарәп-фарсы алынмаларының икеләтелгән күплектә, ягъни *-лар* кушымчасы белән дә килә алуы; б) *-лар* аффиксының билгесез күплекне белдерүе белән бергә, башка мәгънәләр дә (даирә-гаилә, сорт-төрлелек, хис-кичерешләр) аңлата алуы;

3) синтаксиска нигезләнгәне: берлек һәм күплек идеясенең аналитик ысул белән дә белдерелүе, хәзерге әдәби тел белән чагыштырганда, бу мәгънәне алып килә торган сүзләрнең сан ягыннан күбрәк кулланылуы: *ничәсе, күп, чук, горуһ-горуһ, катрә-катрә* һ.б.

Сан категориясендә әдәби норма һәм норма вариантлылыгын тәшкил итә торган әлеге парадигмадан теге яки бу стиль, яисә аның берәр жанр-төренең таләбе белән махсус рәвештә берсенең сайланып кулланылуы функциональ-стилистик вариантлылыкны барлыкка китерә.

Грамматик мәгънәсе ягыннан предметның кайсы затка (икенче предметка) караганлыгын махсус аффиксларда белдерә торган тартым категориясе дә, сан категориясе кебек үк, ике телгә хас булган әдәби норма күрсәткечләре белән тәгъбир ителә: а) хәзерге татар әдәби теленә хас булган ысулда; ә) гарәп-фарсы телендәге сыйфатлау һәм изафә тәркибе (тезмәләре) белән.

Әлеге ике әдәби норманың түбәндәге норма вариантлары күзәтелә: 1) графо-орфографиягә нигезләнгәне: а) I һәм II заттагы тартымлы исемнәрнең күплектә *-мыз, -ңыз* һәм *-быз, -гыз* формасында язылуы; ә) I зат берлектәге алмашлыкларның бәнем, мәнем, минем, күплектә – безем, безнең, II затта – *сәнең, синең,* III затта – *анлар, алар, бонлар, болар* вариантларында булуы; б) II һәм III заттагы берлек һәм күплектәге морфемада (ң) графемасының төрлечә бирелеше; 2) морфологиягә нигезләнгәне: а) I, II, III затка караган тартым мәгънәсенең синтетик һәм аналитик-синтетик ысулда, I һәм II зат тартымның тагын аналитик ысулда да чагылышы; ә) III зат тартымлы исемнәрнең *-сы, -ы, -лары* кушымчалары алуы; б) III зат тартым кушымчасының тартым мәгънәсеннән башка мәгънәләр дә белдерә алуы; в) I, II, III заттагы тартымлы исемнәрдә тартым күрсәткечләренең исемне ачыклап килә торган сыйфат фигыльгә дә күчә алуы; 3) синтаксиска нигезләнгәне: а) аналитик һәм аналитик-синтетик ысулдагы тартымлы исемнәрдә зат һәм предметның кайсы затка караганлыгы, зат алмашлыклары белән рәттән, тагын *үз* һәм *кәнду* сүзләре кулланылып та белдерелә алуы, зат алмашлыкларыннан аермалы буларак, әлеге сүзләрнең тартым һәм килеш күрсәткечләреннән башка да килүе; ә) III затка караган тартымның III зат тартым кушымчалары белән, иялек килешендәге III зат күрсәтү (*бунлар*) алмашлыгы белән, шулай ук тагын берсе иялек килешендәге ике исем белән дә тәгъбир ителә алуы; б) янәшә килгән ике исемнең беренчесе баш килештә,

икенчесе тартым кушымчалы булганда, тартым мәгънәсеннән башка мәгънәләрнең белдерелә алуы.

Тартым категориясендә әдәби норма һәм норма вариантлылыгын тәшкил итә торган әлеге парадигмадан теге яки бу стиль, яисә аның берәр жанр-төренең таләбе белән махсус рәвештә берсенең сайланып кулланылуы функциональ-стилистик вариантлылык барлыкка китерә.

Грамматик мәгънәсе ягыннан исемнәрне башка сүзләр белән бәйләп, аларны үзара төрле синтаксик бәйләнеш-мөнәсәбәттә яшәтә торган килеш категориясенә караган парадигмалардан иялек, юнәлеш һәм төшем килешләре төрки телләрнең угыз һәм кыпчак төркемнәре теленә хас булган ике әдәби нормада кулланыла. Димәк, килеш категориясендә, сан һәм тартым категорияләрендәге кебек, төрле система телләренә хас булган ике әдәби норма түгел, бәлки бер үк гаиләдәге ике төркемнең әдәби нормалары чагылыш таба. Әлеге әдәби нормаларда, шулай ук башка килешләрдә, түбәндәге вариантлылыклар күзәтелә: 1) графо-орфографиягә нигезләнгәне: а) баш килешнең нуль формада булуы; ә) иялек килешендә кыпчак төрләнешендәге исемнәрнең *-ның,* угыз төрләнешендә, сузыкка тәмамланса, *-нң,* тартыкка *-ң* кушымчалары алуы, (ң) графемасының төрлечә язылуы; б) юнәлеш килешендә *-гә/-кә, -га/-ка,* угыз төрләнешендә сузыкка төмамаланса, *-йә,* тартыкка – һаи рәсмия белән ясалуы, (г) графемасының төрлече язылуы; в) төшем килешендә кыпчак төрләнешендәге исемнәр *-ны,* угыз төрләшендә, сузыкка тәмамаланса *-йы,* тартыкка тәмамланса *-и,* III зат тартымлы исемнәрнең *-н* һәм *-ны* кушымчалары белән ясалуы, соңгы күрсәткечтә тартымдагы сузыкның *-и* һәм *-у* рәвешендә языла алуы; г) чыгыш килеше аффиксының әлифле *-дан*, әлифсез *-дән,* шулай ук *-дин* булып язылышы; урын-вакыт килешенең бер генә вариантта булуы; 2) морфологиягә нигезләнгәне: а) традицион алты килешнең төрле мәгънә мөнәсәбәтләрендә, һәрберсенең үз вазифасын башкаруы; ә) традицион алты килеш аффиксларыннан башка тагын *-дагы, -ныкы, -дай, -лы, -сыз* кушымчаларының да килеш вазифаларын үтәүләре; в) бер килеш кушымчасының икенче килешнең мәгънәсен бирүдә файдаланылуы; 3) синтаксиска нигезләнгәне: кайбер килешләрнең мәгънәсе һәм вазифасы, ягъни башка сүзләр белән бәйләнеше, кушымчалар белән дә, шул ук вакытта бәйлек һәм бәйлек сүзләр белән дә белдерелә алуы.

Килеш категориясенә хас булган әдәби норма һәм аның норма вариантлары аерым жанр-стильдә язылган текстларда махсус сайланып

кулланылганга күрә, алар функциональ-стилистик вариантлылык хасил итә. Гомумтөрки укучыга багышлап язылган әсәр һәм хезмәтләрдә иялек, юнәлеш һәм төшем килешләре угыз-көньяк төрләнешендә, татар укучысы өчен дип язылган әдәби әсәрләрдә кыпчак-төньяк төрләнеш күрсәткечләре белән кулланыла. Классиклар иҗатында әлеге мөмкинлекләр образ барлыкка китерү чарасы буларак та файдаланыла.

Сыйфат сүз төркеменә мөнәсәбәтле рәвештә хәзерге грамматикаларда тәгаенләп әйтелмәгән бер теоретик фикергә игътибар ителде. Галимнәр белдерүенә күрә, хәзерге татар телендә сыйфатлар: а) «...мәгънәләрендәге һәм ә) лексик-морфологик формаларындагы аермалыклары буенча, …асыл (качественные) һәм нисби (относительные)…» дигән [Хангильдин, 1954, б. 92–93] төрләргә бүленә [Татар грамматикасы, 2002, б. 67, Хисамова, 2006, б. 116]. Әлеге хезмәтләрдән аңлашылганча, лексик-семантик төрләр саналганда мисал итеп асыл сыйфатлар гына китерелә. Димәк, лексик-семантик төр дигәндә, нисби сыйфатлар искә алынмый була. Лексик-грамматик яктан дип каралганда, асыл сыйфатларның тамыр һәм ясалма булуы, дәрәҗә белдерә алуы истә тотыла, ягъни грамматик чолганышка килеп кергәнче үк билгеле булган структур төзелеше турында әйтелә. Нисби сыйфатлар, асыллардан аермалы буларак, сыйфатланмышлары булган предметларның саф билгесен күрсәтми, нисби билгеләрен генә белдерә, ясалма төрдә генә була, димәк, лексик-грамматик яктан гына характерланалар. Бу мәсьәләгә хәзерге грамматикаларда да игътибар итәргә кирәклек сорала, ягъни «предметның процессуаль булмаган статик билгесен» белдерә торган гоумумкатегориаль нигездә берләшкәнгә кадәр лексик-семантик төрләр дигәндә, асыл сыйфатларның төркемчәләрен генә санарга туры килә, чөнки алар гына «...башка предметка, күренешкә мөнәсәбәтеннән килеп чыкмаган билгеләрен белдерәләр» [Татар грамматикасы, 2002, б. 67]. Шуның белән бергә, гасырлар буена дәвам итеп килә торган әдәби телдә сыйфатларның аерым әсәрдә кулланылышындагы үзенчәлекләренә игътибар итәргә кирәк була. Бу юнәлештә, исем сүз төркеме тикшерелгәндәге кебек, беренчедән, тезмә һәм чәчмә әсәрләрне аерып карарга, икенчедән, авторның үз чоры әдәби теле мөмкинлеген ничек файдалануы, персонажларына карата булган уңай һәм кире мөнәсәбәтенә нисбәтән, сыйфат төркемчәләренең сайланып алынуына, шушы максатның үтәлүенә нигезләнеп, гарәп һәм фарсы алынмаларының кимүгә баруы, өченчедән, зат һәм предметларның билгесен (олуг падишаһ – олуг бина) шулай ук

предметларның да, процессларның да билгесен белдерә торган сыйфатларның (яхшы йорт – яхшы төзелә) һәрдаим дәвам итүе турында әйтелә барылды. Әлеге мәсьәләнең, ягъни сыйфатларның тамыр һәм ясалма халәтендә күп төрле вазифа үтәп кулланылуының Г. Тукай шигъри әсәрләрендә бик катлауланылуы сәбәпле, һәм Г. Тукай, һәм башка классикларыбызның иҗатын махсус рәвештә аерып алып тикшерергә кирәклек күренә.

Сан сүз төркемен тикшеренүләрдән күренгәнчә, мәгънәсе буенча, бер төрдәге предметларныңданә исәбен, микъдарен белдереп, үзенә генә хас булган, *-ынчы/-енче (-нчы/-нче), -ау/-әү, -ар/-әр, -шар/-шәр, -лап/-ләп* ясагыч күрсәткечләре белән, гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә, лексик-грамматик яктан гомумиләшеп, микъдар саны (төп сан), тәртип, җыю, бүлем, чама саны дигән төркемчәләргә берләшә торган сан сүз төркеменең XIX гасырның беренче һәм икенче яртысында иҗат ителгән тезмә әсәрләрдә, XIX гасыр ахыры – XX йөз башындагы чәчмә әсәрләрнең һәрберсендә төрле дәрәҗә кулланылышта булуы аңлашылды. Чәчмә әсәрләрдә чама санының күпчелек очракта үзара якын торган саннарны кабатлау юлы белән ясалган синтаксик ысулда кулланылуының активлыгы күзәтелде.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, рәвеш сүз төркеме лексик-семантик һәм лексик-грамматик мәгънәләре буенча эш-хәл һәм билгеләрнең сыйфатын, күләм-дәрәҗәсен, урынын, вакытын, сәбәбен-максатын белдерә алулары ягыннан, төрле төркемчәләргә бүлеп карарга мөмкин сүзләрнең, предмет һәм затларның процесска бәйле булмаган билгеләрен белдерә торган гомумкатегориаль грамматик мәгънә нигезендә берләшеп, морфологик яктан формалашмаган, ягъни башка сүз төркемнәреннән аера торган формаль күрсәткече булмаган, синтаксик планда, фигыльгә, рәвешкә, сыйфатка, хәбәрлек сүзгә, сирәгрәк исемгә янәшәлек юлы белән бәйләнеп, асылда, хәл, шулай ук аергыч, хәбәр функциясен үти алучы, рәвеш сүз төркеменә караган сүз, сүзформа, сүзтезмәләр XIX гасырның беренче һәм икенче яртысында язылган поэзия әсәрләрендә, XIX гасырның икенче яртысыннан – XX йөз башына кадәр иҗат ителгән чәчмә әсәрләрдә актив кулланышта була.

Алмашлык сүз төркемен тикшерүдән күренгәнчә, күрсәтелгән вакытта иҗат ителгән әсәрләрдә алмашлыкларның барлык төркемчәләре дә кулланылышта була. Һәр автор, башка барлык чаралар кебек үк, алмашлыкларны да максатына туры килерлек дәрәҗәдә сайлап

ала, нәтиҗәдә, алмашлык төркемчәләренең берсе ешрак кабатлана, икенчеләренең сирәгрәк файдаланылуы күзәтелә. Гомумән алганда, әлеге сүз төркеменә караган язма традициянең дәвам ителгән хәлдә, хәзерге әдәби тел нормасының да тотрыклануга баруы күзәтелә.

Фигыль сүз төркеме, хәзерге әдәби телдәге кебек, темпоральлек, модальлек, персональлеккә караган функциональ-семантик категорияләргә нигезләнеп тикшерелә.

Темпоральлек – фигыльдә заман категориясе, чынбарлыкның яшәеш формасы, объектив заманның телдәге чагылышы буларак, эшнең үтәлү-үтәлмәвен реаль факт итеп белдерә торган хикәя фигыльдә, аның заман категорияләренең күрсәткеч-мөмкинлекләрендә чагылыш таба.

Үткән заман хикәя фигыль өйрәнелә торган чорда түбәндәге формаларда кулланыла: синтетик төрләре: *-ды, -ган, -мыш, -ып,* аналитик төрләре: *-ды иде, -ган иде, -мыш иде, -ып иде, -а (дыр) иде, -р иде, -йур иде, -а торган иде, -макда иде, -мак (-лык) иде, -уда иде, -учан иде.* Аңлашылганча, үткән заман хикәя фигыль, өйрәнелә торган чорда, угыз һәм кыпчак телләренә хас булган ике әдәби тел нормасында кулланыла, түбәндәге норма вариантлылыклары күзәтелә: 1) графо-орфографиягә нигезләнгәне: а) I һәм II зат кушымчалары алганда, *-ды* аффиксы сузыклы һәм сузыксыз булып, ә) *-ган* морфемасындагы (г) графемасының калынлыкта-нечкәлектә аерымланып һәм саңгырау тартыгы белән чиратлашып, *-ачак* кушымасында (ч) һәм (ж) тартыкларының алмашынып язылуы; 2) морфологиягә нигезләнгәне: а) үткән заман хикәя фигыль күрсәткечләренең берсе икенчесенең вазифасын үти алуы; ә) үткән заман хикәя фигыльнең күчерелмә мәгънәдә дә кулланылуы; б) башка наклонение төрләренең үткән заман мәгънәсендә килә алулары; 3) синтаксиска нигезләнгәне: *-р иде, -мыш иде* формаларында иде ярдәмлегенең кушылып *(-рды, -мышды)* языла алуы.

Татар әдәби телендәге үткән заман хикәя фигыльнең парадигмасын барлыкка китерә торган әлеге хәзинәдән язма текстның яки стиле, яисә шул стильнең нинди дә булса бер жанр төренең таләбе белән кайсы да булса бер чараның махсус рәвештә сайланып кулланылуы әлеге категориянең функциональ-стилистик вариантлылыгын барлыкка китерә.

Хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыль өйрәнелә торган чорда түбәндәге формаларда чагылыш таба: *-а (дыр), -р, -йур, -маз, -мас, -макда (дыр), -ачак (дыр), -айды, -ады, -гай, -ганди, -гани, -уда, -учан, -асы.*

Аңлашылганча, хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыль, өйрәнелә торган чорда, угыз һәм кыпчак телләренә хас булган ике әдәби тел нормасында кулланыла, түбәндәге норма вариантлылыклары күзәтелә: 1) графо-орфогафиягә нигезләнгәне: бер үк кушымчаның төрлечә языла-әйтелә алуы: *-а, -ай, -и, -әй, -маз, -мәс, -ачак, -аҗак* һ.б.; 2) морфологиягә нигезләнгәне: а) бер үк зат кушымчасының тулы һәм кыскартылган формада була алуы, барлык һәм юклык күрсәткечләренең төрле формада кулланыла алуы, ә) хәзерге-киләчәк заман формаларының үткән заман һәм башка наклонение мәгънәләрендә һәм шулай ук, киресенчә, башка формаларның хәзерге-киләчәк заман мәгънәсендә кулланыла алуы; 3) синтаксиска нигезләнгәне: фигыль формалары белән белдерелә торган мәгънәләрнең лексик чаралар белән дә көчәйтелүе.

Әлеге заманнар парадигмасын барлыкка китерә торган шушы хәзинәдән бер форманың махсус сайланып алынып, ешрак кабатланып кулланылышы әлеге категориянең функциональ-стилистик вариантлылыгын барлыкка китерә.

Сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерә торган модальлек функциональ-семантик категориясе, эш яки хәлнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен махсус кушымчалар белән белдерә торган наклонение дигән грамматик категорияләрендә реальләшә: эшнең үтәлүен-үтәлмәвен, чынбарлыктагы өч заманны тугыз формада реаль факт итеп белдерә торган хикәяләү наклонениесе белән бергә, эшнең реаль булмавын белдерә торган, боеру, теләк, шарт, кире шарт, шартлы теләк һәм ният наклонениеләре, һәрберсе үзләренең категориаль мәгънәләре, шул мәгънәне белдерә торган грамматик күрсәткечләре белән хәрәкәттә, яшәештә була. Матур әдәбият әсәрләрендә авторның индивидуаль осталыгын, хикәяләүнең төрләрен дөрес аңларга, башка стильләрнең табигатен һәм вазифасын билгеләргә мөмкинлек бирә, нигез булып тора.

XIII гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән төрле жанр-стильдәге әдәби әсәрләрдә боеру наклонениесе нуль форма, *-саң, -ың, -ыңыз, -ыгыз, -гыл, -сын (-сун), -сыннар (-сунлар)* формалары белән белдерелә. Әлеге фигыль угыз һәм кыпчак телләренә хас булган ике әдәби тел нормасында файдаланыла, аерым графемаларның төрлечә язылышында чагылыш табып, графо-орфографиягә нигезленгән, һәм бер үк морфеманың төрле контекстта төрле вазифа үти алуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән морфологик вариантлылык хасил итә.

XIII гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән төрле жанр-стильдәге әдәби әсәрләрдә теләк наклонениесе, *-гай* күрсәткеченең фонетик үзгәрешенә нигезләнеп, киң һәм тар язылышта кулланыла торган *-айым, -ыйм, -айык, -ыйк* формалары белән тагын *-айын, -але, -алем, -алек* кушымчалары белән дә белдерелә. Әлеге формаларның файдаланылуында, билгеле бер дәрәҗәдә, эш бүленеше күзәтелә, ягъни төрле жанр-стильдә язылган текстларда алар төрле ешлыкта кабатлана һәм, хронологиягә бәйле рәвештә, активлык һәм пассивлыкларын үзгәртәләр.

*-алем* формасы, югары стиль чарасы буларак, сәнгатьле сөйләмнең барлык жанрларында да файдаланыла, мәгърифәтче әдипләр иҗатында әдипнең укучысына эндәшеп хикәяләвен дәвам иттерү чарасы буларак күтәрелә һәм шулай ук, драма әсәрләрендәге кебек, персонажларның үзара сөйләшүендә, нәзакәтлелекне белдерә. Г. Тукай иҗатының башлангыч чорында әлеге кушымча гади информация чарасы буларак, аннан соң борынгылыкны – искелекне сурәтләү, стилизация чарасы буларак сайланып алына.

Классик әдипләр иҗатында әлеге форма һәм аларның вазифалары татар халкының җанлы сөйләмә нормасы белән алмаштырыла, ягъни теләк фигыль сүз нигезендәге сузыкка бәйле булган *-ыйм, -им, -ыйк, -ик* вариантлылыгын хасил иткән, тар язылыштагы формасы белән генә сакланып кала.

XIII гасыр – XX йөз башында төрле жанр-стильдә язылган әдәбиятта шартлы теләкне белдерә торган җөмләләр, нигездә, түбәндәгечә төзелә: шарт мәгънәсенең күрсәткече – *-са, -р исә, -са иде* формалары, теләк мәгънәсен *-р иде, -ачак иде, -ган булыр иде* формалары белдерә. Шуның белән бергә, аерым әдипләрнең кайбер әсәрләрендә, шарт мәгънәсе *-ганда, -ганга, -гач* күрсәткечле хәл фигыльләр белән дә белдерелә ала. Әлеге формаларның һәрберсе үзләренә хас булган мәгънә төсмере белән кулланыла. Классик әдипләр иҗатында җанлы сөйләмдә актив файдаланыла торган *-са* кушымчасы чагылыш тапкан тотрыклы тезмәләр һәм кабатлана торган формалар ныклы урын ала. Һәр форманы автор үзенең аерым бер әсәренең образлар системасына туры килгәннәрен сайлап ала, тасвир чарасы итеп китерә.

XIII гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән төрле жанр-стильдәге әсәрләрдә, уңай һәм кире шарт мәгънәсе *-са, -са да, -ды исә (дә), -мыш исә (дә), -ган исә (дә), -р исә (дә), -йур исә (дә), -маз исә (дә), -мас исә (дә), -макда исә (дә), -ачак исә (дә), -ып исә, -са кирәк, -са иде*

формаларында чагылыш таба. Шулай итеп, шарт фигыль, өйрәнелә торган чорда, угыз һәм кыпчак телләренә хас булган ике әдәби тел нормасында кулланыла, графо-орфографик һәм морфологик вариантлылык хасил итә. Әлеге күрсәткечләрнең файдаланылуында, билгеле бер дәрәҗәдә, эш бүленеше күзәтелә, ягъни төрле жанр-стильдә язылган текстларда алар төрле ешлыкта кабатлана һәм хронологиягә бәйле рәвештә дә үзләренең активлык һәм пассивлыкларын үзгәртәләр, шул нигездә функциональ-стилистик вариантлылык барлыкка килә.

К. Насыйри, Ә. Уразаев-Кормаши, Т. Яхин әсәрләрендә шарт фигыльнең, нигездә, *-са, -са да, -са кирәк* формалары кулланыла.

М. Акъегет, З. Бигиев, Р. Фәхретдин иҗатында, шарт фигыльнең әлеге формалары белән бергә, угыз телләренә хас булган фигыль күрсәткечләре һәм *исә* ярдәмлеге белән барлыкка килгән аналитик төзелмәле шарт фигыльләре актив файдаланыла. Бу төр төзелмәләр Ф. Кәриминең сәнгатьле проза әсәрләрендә, гадәттә, уртак сөйләмне һәм персонажларның үзара сөйләшүен сурәтләгән юлларда чагылыш таба.

Әлеге үзенчәлек классик әдипләр иҗатында да дәвам итеlә, ягъни татар әдәби теленең җәдиди госманлы варианты белән язылган текстларда эзлекле булып кулланыла торган тезмә формалы шарт фигыльләрен файдалану бик сирәгәя, *-са* кушымчалы шарт фигыльнең мәгънәсе баш җөмләдә килә торган төп фигыльнең заман һәм наклонениесенә ныграк бәйләнә, хәзерге әдәби телдә норма буларак карала торган мәгънә төсмерләре барлыкка килә, *-са* кушымчасы чагылыш тапкан һәм җанлы сөйләмдә актив яшәештә булып ныгыган төзелмәләр ешрак кабатлана, шартлы теләкне белдерә торган фигыль формалары активлаша, боларның барысы да һәр авторның һәр әсәренә кирәк дәрәҗәдә сайланып алына.

XIII гасыр – XX йөз башында иҗат ителгән әдәби әсәрләрдә аерым наклонение буларак формалашкан ният фигыль кулланыла. Фигыльнең нигезен тәшкил итә торган *-макчы* күрсәткеченнән башка, бу фигыльнең мәгънәсе, хәзерге әдәби телдә һәм сөйләшләрдәге кебек үк, төрле аналитик формалар белән дә тәгъбир ителә: *-макчы бул-, -макчы иде-, -мак бул-, -ырга бул-, -ачак бул-, -ырга кели, -ырга тели, -мак тели, -мага тели, -ыйм, -ыйк ди-* шуның белән бергә, өйрәнелә торган чорда язылган текстларда аналитик формаларның тагын да күбрәк кулланылуы күзәтелә: *-макчы ул-, -мак ул-, -ачак ул-, -мак эстәү, -мага ният илә, -мак касды, -мага рәгъбәт итү, -мага хәммә кыйлу, -мага һиммәт баглау* һ.б. Шулай итеп, ният мәгънәсен белдерә

торган формалар, өйрәнелә торган чорда, угыз һәм кыпчак телләренә хас булган ике әдәби тел нормасында кулланыла, графо-орфографик һәм морфологик вариантлыльк хасил итә. Әлеге күрсәткечләрнең файдаланылуында, билгеле бер дәрәҗәдә, эш бүленеше күзәтелә, ягъни аерым әдипләрнең әсәрләрендә, ният мәгънәсен белдерә торган формаларның яки берничәсе, яки, нигездә, берсе генә эзлекле актив кабатлана, димәк, әлеге фигыльнең кулланылышында да функциональ-стилистик вариантлылык хасил була.

Хронологиягә бәйле рәвештә караганда язма традицион аналитик формаларның пассивлаша баруы күзәтелә. Классик әдипләр иҗатында ният мәгънәсен, нигездә, *-макчы* һәм *-ырга* кушымчаларының *бул* һәм *иде* ярдәмлекләре белән бергә төзелгән формада белдерү эзлекле файдаланыла.

Утилитар стильләрдә бу фигыльнең кулланылуы, матур әдәбият әсәрләре белән чагыштырганда, шактый сирәк күзәтелә.

Персональлек-зат категориясе нигезендә фигыльләр затланышлы һәм затланышсыз дип ике төркемгә бүлеп карала. Югарыда искә алынган барлык наклонениеләр дә, фигыльнең затланышлы формалары буларак, берьюлы затны-санны белдерә торган берлектә һәм күплектәге тулы һәм кыска кушымча алып алты формадагагы ике параллель парадигма хасил итәләр. Күрсәтелгән дәвердә иҗат ителгән әдәби әсәрләрдә бу кушымчалар белән мәгънә белдерелгәндә, графо-орфографик вариантлылык алып файдаланылуы күзәтелә.

Сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль, инфинитив кебек зат категориясенә ия булмаган фигыль формаларында фигыль мәгънәсе көчсезләнә, чөнки предмет билгесе, эш-хәл билгесе, предметлык кебек мәгънәләр өстәлә. Бу мәгънәләр һәр фигыльнең үзенә хас булган күрсәткечләре белән белдерелә. Хәзерге әдәбият белән чагыштырганда, башка барлык фигыльләрдәге кебек үк, кушымчаларның сан ягыннан күбрәк булуы күзәтелә, әдәби тел тарихыбызда, ерак гасырларны узып дәвам итә торган традицион формалар белән бергә, хәзерге әдәби телдә һәм сөйләшләребездә файдаланыла торган күпчелек кушымчалар да кулланылышта була.

# ӘДӘБИЯТ

## Чыганаклар

Акмулла. Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе / Акмулла. – Казан: Типо-литография ун-та, 1892. – 15 б.

Акмулла М. Шигырьләр / төз., кереш сүз, искәрмәләр һәм аңлатмалар авторы Ф. Яхин. – Казан: ТДГИ нәшр., 2001. – 96 б.

Акъегет М. Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. – Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. – 70 б.

Ахметгалеева Я.С. Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы» / Я.С. Ахметгалеева. – М.: Наука, 1979. – С. 124–143.

Әмирхан Ф. Гарәфә кич төшемдә / Ф. Әмирхан // Әльислях. – 1907. – № 4.

Әмирхан Ф. Әдәбиятка гаид / Ф. Әмирхан // Әльислях. – 1908. – 8 сентябрь, № 44, 30 сентябрь, № 47.

Әмирхан Ф. Гарәфә кич төшемдә. Хыялый хикәя / Ф. Әмирхан. – Казан: Юл, 1909. – 6 нчы китап. – 16 б.

Әмирхан Ф. Татар кызы. Беренче басылуы / Ф. Әмирхан. – Казан: Үрнәк; Гасыр, 1909. – 5 нче китап. – 20 б.

Әмирхан Ф. Татар кызы. Кульязма // Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 16 ф. 1 тасв. 49 эш. – Казан, 1925. – Ике дәфтәрдә.

Әмирхан Ф. Вак-төяк. Өч хикәя / Ф. Әмирхан. – Казан: Харитонов матбагасы, 1909. – 30 б.

Әмирхан Ф. Танымаганлыктан таныштык. Милли хикәя / Ф. Әмирхан. – Казан: Юл, 1909. – 62 б.

Әмирхан Ф. Фәтхулла хәзрәт. Беренче басма, 1 нче җөзъә / Ф. Әмирхан. – Казан: Үрнәк, 1909. – 32 б.; 2 нче җөзьә – 31 б.; 3 нче җөзьә – 31 б.; 4 нче җөзьә – 27 б.; 5 нче җөзьә – 32 б.

Әмирхан Ф. Көндезге сәхәр яки рузасызлар. Заман хикәячесе / Ф. Әмирхан. – Казан: Лито-типография И.Н. Харитонова, 1911. – 16 б.

Әмирхан Ф. Хәят. 1 нче бүлек. Милли хикәя / Ф. Әмирхан. – Казан: Юл китапханәсе, 38 нче китап, 1911. – 38 б.

Әмирхан Ф. Кадерле минутлар. Хикәя. Беренче табгы. / Ф. Әмирхан. – Казан: тип. И. Н. Харитонова, 1912. – Юл китабханәсе, 57 нче китап. – 1912. – 51б.

Әмирхан Ф. Әсәрләр. Дүрт томда. 1 том. Хикәяләр / Ф. Әмирхан. – 1907 – 1922. – Казан: Татар. кит. нәш., 1984. – 478 б.

Әмирхан Ф. Әсәрләр. Дүрт томда. 2 том. Повестьлар, роман һәм драма әсәрләре / Ф. Әмирхан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 486 б.

Әмирхан Ф. Әсәрләр. Дүрт томда. 3том. Публицистика / Ф. Әмирхан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 511 б.

Әмирхан Ф. Әсәрләр. Дүрт томда. 4 том. Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар / Ф. Әмирхан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 390 б.

Баласагунский Юсуф. Благодатное знание / перевод С.Н. Иванова. – М.: Наука, 1983. – 558 с.

Батырша (Алиев Г.). Гарызнамә (Трактат) / мирас ядкарен текстологик яктан филология фәннәре докторы Мәсгүд Гайнетдинов әзерләде // «Мирас» китапханәсе, 2000. – № 11. – Б. 122–130; Мирас. – № 12. – Б. 68–81; Мирас. – 2001. – № 1. – Б. 56–65.

Батырша (Габдулла Алиев) / кереш, искәрмәләр һәм комментарийлар язучы М. Әхмәтҗанов // XVIII йөз татар әдәбияты: Проза. – Казан: Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2012. – Б. 107–162; 388–407.

Баязитов Г. Тел бәхәсе / Г. Баязитов // Нур (СП.). – 1905. – № 4; 1906. – № 67.

Бигиев З. Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә: роман. – Казан: Типогр. Г.М. Вечеслава, 1887. – 77 б.

Бигиев З. Гөнаһе кәбаир: роман. – Казан: Типогр. Г.М. Вечеслава, 1890. – 72 б.

Бигиев З. Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр). – Казан: типолитогр. И.В. Ермолаевой, 1908. – 108 б.

Бигиев З. Зур гөнаһлар: романнар, сәяхәтнамә / җыентыкны төзүче, төп текстның транскрипциясен, хәзерге әдәби телгә тәрҗемәсен эшләүче, искәрмәләр, ахыр сүз авторы Р. Даутов. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1991. – 380 б.

Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары: уку-укыту әсбабы / төз. Х. Госман. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981. – 246 б.

Будагов Л.З. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий / Л.З. Будагов. – СПб., 1871. – Т. II.

Вәлиди Җ. Сайланма хезмәтләр: әдәби тел, грамматика, диалектология һәм лексикография мәсьәләләре / Җамал Вәлиди. – Казан: Мәгариф, 2007. – 271 б.

Габәши Х.-Г. Җавап / Х.-Г. Габәши // Нур. – 1905. – № 13.

Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари. Шигырьләр, поэмалар / төзүче, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче, кереш сүз авторы, юлга-юл тәрҗемәләрне эшләүче – Әнвәр Шәрипов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 397 б.

Габдессәләм. Илаһи бәйет // XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. – Казан: Дом печати, 2006. – Б. 41–73.

Габди. Башлам. Бисмиллаһи дийә күңел // XVIII гасыр татар әдәбияты: Поэзия. – Казан: Дом печати, 2006. – Б. 13–30.

Гафуров-Чыгтай Г. Тутам / Г. Гафуров-Чыгтай. – Казан: Китаб., 1908.

Зәки Ш. Шигырьләре / Р. Фәхретдин. Асар. – Оренбург, 1907. – 13 җөзьә, 2 җилд. – Б. 415 – 419.

Зәки Шәмсетдин. Мөнәҗәтләр. Хикәятләр / төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы Мәсгуд Гайнетдин. – Казан: Иман, 2002/1423. – Б. 3–13, 29–61, 125–152.

Ибраһимов Г. Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы / Г. Ибраһимов // Әлислах. 1907. – № 2 – 1908. – № 36; Казан: Өмид, 1912.

Ибраһимов Г. Йаз башы. Бер шәкертдән хикәят / Г. Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 1910. – 5 нче китаб.

Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – I т. Хикәяләр (1907–1929). – 509 б.

Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – II т.: Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. – 477 б.

Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – V т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910 – 1933). – 615 б.

Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда / фәнни ред., кереш сүз, искәрмә һәм аңлатмаларның авторы Ф. Фәсиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – VIII т.: Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). – 431 б.

Ибраһимов Г. Милләт. Тел. Әдәбият: сайланма хезмәтләр / Г. Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2007. – 239 б.

Ильяси Г. Бичара кыз: фаҗига / Г. Ильяси. – Казан: Казан ун-ты типогр., 1887.

Иманколый С. Салятыйн исламдан беренче җөзьә / С. Иманколый. – Казан: Электротип. «Үрнәк», 1909. – 65 б.

Исламова А.И. Исследование языка тюркско-татарского памятника XIV в. «Дастан-и Джумджума Султан» Хисама Кятиба: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1998. – С. 39–62.

История татарского литературного языка (XIII – первая четверть XX в. ) / сост. и ответ. ред. Х. Курбатов. – Казань: Фикер, 2003. – 656 с.

Исхакый Г. Кәләпүшче кыз: хикәя / Г. Исхакый. – Казан: Литотип. Б.Л. Домбровского, 1902. – 42 б.

Исхакый Г. Пушкин А.С. Капитан кызы / Г. Исхакый. – Казан: Литотип. И.Н. Харитонова, 1902. – 56 б.

Исхакый Г. Ике йөз йылдан соң инкыйраз / Г. Исхакый. – Казан: Литотип. И.Н. Харитонова, 1904. – 96 б.

Исхакый Г. Җавап / Г. Исхакый // Нур (СПб.), 1905. – № 5.

Исхакый Г. Бай угълы: роман / Г. Исхакый // Мөхәмәдгаяз әл-Исхакыйның мәҗмугаи асаре. – Казань: Литотип. И.Н. Харитонова, 1910. – 1 нче җилд, 4 нче китап. – Б. 161–224.

Исхакый Г. Тормышмы бу?: роман / Г. Исхакый // Мөхәммәдгаяз әл-Исхакыйның мәҗмугаи асаре. – Казань: Литотип. И.Н. Харитонова, 1911. – 1 җилд, 2 нче китап. – Б. 3–103.

Исхакый Г. Кияү: хикәя. Беренче табгы / Г. Исхакый // Мөхәммәдгаяз әл-Исхакыйның мәҗмугаи асаре. – Казань: Литотип. И.Н. Харитонова, 1911. – 2 нче җилд, 3 нче китап. – Б. 136–191.

Исхакый Г. Мулла бабай: роман. // Мөхәммәдгаяз әл-Исхакыйның мәҗмугаи асаре. – Казань: Литотип. И.Н. Харитонова, 1913, 4 нче җилд. – 280 б.

Исхакый Г. Остазбикә / Г. Исхакый // Мөхәммәдгаяз әл-Исхакыйның мәҗмугаи асаре. – М.: Тип-фия М.О. Аттая и К$^{О}$, 1915. – 8 нче җилд, 1 нче китап. – Б. 2–79.

Исхакый Г. Ул икеләнә иде: хикәя. / Г. Исхакый // Мөхәммәдгаяз әл-Исхакыйның мәҗмугаи асаре. – Казан: Гасыр, 1917. – 8 нче җилд, 2 нче китап. – Б. 3 – 64.

Исхакый Г. Зиндан: сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре / Г. Исхакый. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 670 б.

Исхакый Г. Әсәрләр: унбиш томда / Г. Исхакый. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – I т. Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). – 399 б.

Камал Г. Бәхетсез егет / Г. Камал. – Казан: Электротип. Шарафъ, 1907. – 108 б.

Камал Г. Әсәрләр: 3 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – I т. Пьесалар. – 406 б.

Камал Ш. Уяну / Ш. Камал. – Оренбург: Шура, 1909. № 8, № 12. – 379 б.

Кандалый Г. Сахибҗәмал: Мелла Габделҗаббар әл-Кандалый иншасы // Габделкаюм Насыйри. Фәвакиһ-ел җөләсә фи-л-әдәбият. – Казан: Казан ун-ты тип., 1884. – Б. 559–579.

Кандалый Г. Фәрхи: Мелла Габделҗаббар әл-Кандалый иншасы // Габделкаюм Насыйри. Фәвакиһ-ел җөләсә фи-л-әдәбият. – Казан: Казан ун-ты тип., 1884. – Б. 581–583.

Кандалый Г. Сахибҗәмал: өзекләр // Җ. Вәлидов. Татар әдәбиятының барышы. – Оренбург: Вакт, 1912. – Б. 93 – 98.

Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар / төз., текст һәм искәрмәләрне әзерләүче, кереш сүз авторы М. Госманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 558 б.

Каргалый Ә. Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди: Ошбу китаб йәгъни Сәгыйд бистәсенең хаҗи Әбелмәних мәрхүмнең Тәфсир Кәбирдән вә Мөшкәт әл-Нурадан тәрҗемә ителгән әүлияләр кыйссасы /Казан университетының табгыханәсендә Рәхмәтулла Әмирҗан угылының харәҗате илә табгуланды. – Казан: Ун-т табгыханәсе, 1845. – 51 б.

Каргалый Ә. Мөнәҗәт әл-хаҗи Әбү әл-Мәних – әл-Каргалый // Өмми Камал китабы. – Казан: Ун-т табгыханәсе, 1884. – Б. 108–109.

Каргалый Ә. Изанәмаи хаҗи мәрхүм Мөхәммәд бай мәрхүмгә // Өмми Камал китабы. – Казан: Ун-т табгыханәсе, 1884. – Б. 109.

Каргалый Ә. Тәхрир әл-Хөҗҗел мәрхүм. Галәм әйванында // Өмми Камал китабы. – Казан: Ун-т табгыханәсе, 1884. – Б. 112.

Каргалый Ә. Тәрҗемәи хаҗи әл-Бистәви әс-Сәгыйди. – Казан: Ун-т табгыханәсе, 1889. – 34 б.

Каргалый Әбелмәних. Мөнәҗәтләр. Хикәятләр / төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы Мәсгуд Гайнетдин. – Казан: Иман, 2002 / 1423. – Б. 14–28, 62–124.

Кашгарый М. Диван лугат ат-Турк // Махмуд ал-Кашгарый / перевод, предисловие и комментарии З.-А.М. Ауэзовой; индексы составлены Р. Эрмерсом. – Алматы: Дайк-Пресс, 2005. – 1288 с. +2 с. вкл.

Кәрими Ф. Бер шәкерт илә бер студент / Ф. Кәрими. – Казан: Тип. Б.Л. Домбровского, 1899.

Кәрими Ф. Җиһангир мәхдүмнең ауыл мәктәбендә укуы (Торналы ауылының мәктәбендә) / Ф. Кәрими. – СПб.: Тип. Брагинского, 1900.

Кәрими Ф. Салих бабайның өйләнүе / Ф. Кәрими. – Оренбург: Вакт, 1901.

Кәрими Ф. Йаурупа сәяхәтнамәсе. – Оренбург: Вакт, 1902. – 191 б.

Кәрими Ф. Мәрхүм Гыйльман ахунд / Ф. Кәрими. – Оренбург: Тип. М.-Ф.Г. Каримова, 1903.

Кәрими Ф. Мөхтәсар җәгърафия / Ф. Кәрими. – Казан: Тип. И.Н. Харитонова, 1904.

Кәрими Ф. Андан-бундан / Ф. Кәрими. – Оренбург: Вакт, 1907.

Кәрими Ф. Кырым сәяхәте. – Оренбург: Типогр. М.-Ф. Каримова, 1908. – 116 б.

Кәрими Ф. Истанбул мәктүбләре / Ф. Кәрими. – Оренбург: Вакт, 1913.

Кәрими Ф. Морза кызы Фатыйма: сайланма әсәрләр / Ф. Кәрими. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 414 б.

Кол Гали. Кыйссаи Йосыф / төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кульязмаларның тасвирламасын ясаучы филология фәннәре кандидаты Ф. С. Фәсиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 542 б.

Кол Шәриф. И күңел, бу дөньядыр: газәлләр, кыйсса / җыентыкны төзүче, текст һәм искәрмәләрне әзерләүче, текстларның юлын-юлга тәрҗемә итүче, кереш сүз авторы филология фәннәре кандидаты Әнвәр Шәрипов. –Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – Б. 3–75.

Кол Шәриф (Шәриф Хаҗитархани). Зафәрнамәи вилаяте Казан (Казан вилаятенең җиңүе) / төзүче, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче, кереш сүз авторы Марсель Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – Б. 76 – 93.

Китабы мөстәтаб фәүзел нәҗәт. – Казань: Типо-литография Императорского ун-та, 1895. – 108 с.

Максуди Ә.-Һ. Җавап / Ә-Һ. Максуди // Нур. – СПб., 1905, № 13.

Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. Тексты и исследования. – М., 1951. – С. 323–341.

Мәрҗани Ш. Мөстәфадел – әхбәр фи әхвәли Казан вә Болгар (Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989, 415 б.

Мәүлә Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты», «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Р.Ф. Мәрданов. – Казан: Милли китап, 2008. – 88 б.

Мәхмүд әл-Болгари. Нәһҗел-фәрадис / әсәрне басмага әзерләүче (кульязмадагы текстны укып, гарәп графикасыннан гамәлдәге язуга күчерүче), кереш мәкалә авторы Ф.Ш. Нуриева. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 384 б.

Мелиоранский П.М. Сказание о пророке Салихе // Сб. ст. – СПб., 1897. – 281 с.

Мөслими. Тәварихы Болгария (Болгар тарихы) / Китапны басмага әзерләүче, сүзлек һәм аңлатмалар авторы С. Гыйләҗетдинов. – Казан: Иман, 1999. – 100 б.

Мөхәммәдъяр. Нуры содур: поэмалар, шигырь / Мөхәммәдъяр әсәрләренең тәнкыйди нөсхәсен, хәзерге телгә тәрҗемәсен, кереш сүзне, искәрмәләр һәм аңлатмаларны Ш. Абилов башкарды. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 336 б.

Насыйри К. Казан календаре 1873 нче елга, кәбисә йылының соңындагы әүвәлге йыл. 365 көн / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1873. – 66 б.

Насыйри К. Кырык бакча / К. Насыйри. – Казан: Перов. лит., 1880. – 58 б.

Насыйри К. Әхляк рисаләсе. Әүвәл мәртәбә басыла / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1881. – 32 б.

Насыйри К. Кырык вәзир кыйссасы: өченче басма / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1883. – 165 б.

Насыйри К. Әбүгалисина кыйссасы: дүртенче басма. – Казан: Ун-т тип., 1898. – 112 б.

Насыйри К. Фәвакиһел җөләса фил әдәбият / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1884. – 615 б.

Насыйри К. Истыйляхате җәгърәфия / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1890. – 74б.

Насыйри К. Җәваһирел хикәят / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1884. – 139 б.

Насыйри К. Кавагыйде китабәте / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1892. – 24 б.

Насыйри К. Тәрбия китабы / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1891. – 32 б.

Насыйри К. Мәнафигъ әгъза вә кануны сыйххәт / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1893. – 31 б.

Насыйри К. Гөлзар вә чәмәнзар, йәгъни үләнлек вә чәчәклек / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1894. – 112 б.

Насыйри К. Әнмүзәҗ / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1895. – 87 б.

Насыйри К. Мәҗмәгыл әхбар / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1895. – 176 б.

Насыйри К. Истыйляхате гыйльме һәндәсә / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1895. – 24 б.

Насыйри К. Гакаид рисаләсе / К. Насыйри. – Казан: Ун-т тип., 1896. – 24 б.

Насыйри К. Ләһҗәи татари... / К. Насыйри. – Әүвәл җилд. – Казан: Ун-т тип., 1896. – 220 б.

Насыйри К. Сайланма әсәрләр: ике томда / К. Насыйри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – I т. – 340 б.

Насыйри К. Сайланма әсәрләр: ике томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. II т. – 318 б.

Нуриева Ф.Ш. Тюркоязычный памятник «Ана вә угыл дастаны» // Языковые уровни и их анализ (на материале языков разных систем). – Казань: Изд-во ТГГИ, 2000. – С. 46–73.

Өметбаев М. Татар нәхүсенең мохтәсаре / М. Өметбаев. – Казань: Тип. Б.Л. Домбровского, 1901. – 52 б.

Радлов В. Белек. Балалар укыр өчен чыгарылган китап / В. Радлов. – Казан: Ун-тип., 1872.

Рахманколый Г.С. Монтазам кыйраәт китабы. Беренче җөзьә / Г.С. Рахманколый. – Казань: Типогр. И.Н. Харитонова, 1912. – 44 б.

Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек: элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек / И.Г. Рәми, Р.Н. Даутов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 399.

Салихов Һ. Китабе мәҗмәгыл адәб. Ошбу мәҗмәгыл китабы Казан университетының табгыханәсендә Әлдермеш илендә мәншүрле имам менла Хәсән менла Сәлимҗан углының хәраҗаты илән мөттәфикан әл-мөсәлләм әүвәл кәррә табгы улынды. – Казан: Ун-т табгыханәсе, 1856. – 144 б.

Салихов Һ. Китабе мәҗмәгыл адәб / Һ. Салихов. – Казан: Ун-т табгыханәсе, 1858. – 38 б.

Салихов Һ. Китабе мәҗмәгыл адәб / Һ. Салихов. – Казан: Ун-т табгыханәсе, 1900. – 96 б.

Салихов Һ. Китабе мәҗмәгыл адәб / Һ. Салихов. – Казан: Ун-т табгыханәсе, 1903. – 96 б.

Татар әдәбияты. XIX йөз: югары уку йортлары өчен. – Казан: Таткнигоиздат: укыту – педагогика әдәбият редакциясе, 1957. – 654 б.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – I т.: Урта гасырлар дәвере. – 567 б.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – II т.: XIX йөз татар әдәбияты. – 575 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – I т.: Борынгы чор һәм урта гасырлар. – 415 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – II т.: XV–XVIII гасырлар. – 471 б.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). – Казан: ТӘҺСИ, 2015. – I т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. – 696 б.

Татар мәгърифәтчелек әдәбияты (1860–1905) / төз., сүз башы һәм биографик белешмәләрне язучы М.Х. Гайнуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 415 б.

Татар поэзиясе антологиясе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – Т. I. – 543 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.

Тәфсире һәфтияк мин тәфсире тибъян. – Казан, 1895.

Тәфсире һәфтияккә яңа тәфсире бәян. – Казан, 1897.

Тукаев Мөхәммәтшакир. Тарихы Эстәрлебаш / М. Тукаев. – Казан, 1899. – 196.

Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда / Г. Тукай. – Казан: Таткнигоиздат, 1955. – I т.: 1905 – 1908 еллар. – 282 б.

Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда / Г. Тукай. – Казан: Таткнигоиздат, 1955. – II т.: 1909 – 1913 еллар. – 376 б.

Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда / Г. Тукай. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – III т.: Мәкаләләр, фельетоннар һәм хикәяләр (1906–1908). – 359 б.

Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда / Г. Тукай. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – IV т.: Мәкаләләр, очерклар һәм фельетоннар, 1909–1913 еллар. – 358 б.

Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Г. Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр. 1985. – I т.: Шигырьләр. Поэмалар (1901–1908). – 406 б.

Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Г. Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр. 1985. – II т.: Шигырьләр. Поэмалар (1909–1913). – 400 б.

Тукай Г. Әсәрләр: биш томда / Г. Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр. 1986 – V т.: Истәлекләр, юлъязмалар, хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913).

Тукай Г. Шигърият теле: Сүзлек. 2 китапта. 1 нче китап / К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримуллина. – Казан: Мәгариф 2009. – 503 б.

Тукай Г. Шигърият теле: Сүзлек. 2 китапта. 2 нче китап / К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримуллина. – Казан: Мәгариф 2009. – 527 б.

Уразаев-Кормаши Ә. Кыйссаи Бүз йегет / Ә. Уразаев-Кормаши: беренче басма. – Казан: Ун-т тип., 1874. – 72 б.

Уразаев-Кормаши Ә. Кыйссаи Таһир илә Зөһрә / Ә. Уразаев-Кормаши. – Казан: Тип. наследников М. Чирковой, 1894. – 50 б.

Утыз Имәни-әл-Болгари. Шигырьләр һәм поэмалар / төз. Ә. Шәрипов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 397 б.

Утыз Имәни Г. Инказ әл-халикин // Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ Язма һәм музыкаль мирас үзәге. – 39 фонд. – 44 сакл. бер. – Б. 66–95.

Фәизхан Г. Татар телигә кыскача гыйльме сарыф / Г. Фәизхан. – Казан: Ун-т тип., 1887. – 32 б.

Фәизхан Г. Татар телигә кыскача гыйльме сарыф / текстны транскрипцияләү, хезмәттә кулланылган терминнарның гарәпчә-татарча-русча сүзлекчәсен төзү, мисалларны гарәп графикасында язу Гүзәл Ринат кызы Мөстәкыймова тарафыннан башкарылды. – Казан: Школа, 2005. – 60 б.

Фәизхан Г. Хикәят вә мәкаләт / Г. Фәизхан. – Казан: тип. ун-т, 1889.

Фәизхан Г. Тарих шәҗәрәи төрек. Әбү әл-Гази Боһадирхан бине гарәб Мөхәммәдхан әл-Чыңгызи әл-әүәр зәминең тәэлифедер... / Г. Фәизхан. – Казан: Ун-т тип., 1891. – 226 б.

Фәизхан Г. Календарь 1893 йылга / Г. Фәизхан. – Казан: Типо-лит. наследников М. Чирковой, 1893. – 28 б.

Фәизхан Г. Китабе мөхәррик әл-фикрә. Русия мәмләкәтендә улан татар исламларының гыйлем мәгърифәтләре һәм кәсеб вә һөнәрләренә нә дәрәҗәдә улдыгындан бәхәс әйләйүр. Габделгалләм Фәизхан углының тәэлифкәрдәсидер / Г. Фәизхан. – Казань: Ун-т тип., 1893. – 46 б.

Фәизхан Г. Тутыйнамә китабы / Г. Фәизхан. – Казан: Типо-лит. наследников М. Чирковой, 1896. – 142 б.

Фәхретдин Р. Тәрбияле бала. Ачык ана дилемездә йазылмышдыр / Р. Фәхретдин. – Казан: Типо-лит. наследников М. Чирковой, 1898. – 16 б.

Фәхретдин Р. Тәрбияле хатын. Хөрмәтле галимләр әсәрендән җыелды. Һәрбер өйдә вә һәрбер хатын кулында бу китабдан бер данәсе булынурга тиешледер / Р. Фәхретдин. – Казань: Тип. Б.Л. Домбровского 1899. – 29 б.

Фәхретдин Р. Сәлимә йәки Гыйффәт. Гафил бине Габдулла әсәре уларак бер хикәятдер / Р. Фәхретдин. – Казан: Тип. Б.Л. Домбровского, 1899. – 80 б.

Фәхретдин Р. Әсма йәки Гамәл вә җәза / Р. Фәхретдин. – Оренбург: тип. М.-Ф. Г. Каримова, 1903. – 128 б.

Фәхретдин Р. Мәшһүр хатынлар / Р. Фәхретдин. – Оренбург, 1903. – 448 б.

Фәхретдин Р. Асар. Икенче җилд, тугызынчы җөзьә / Р. Фәхретдин. – Оренбург: Тип. М.-Ф. Г. Каримова, 1905. – 93 б.

Фәхретдин Р. Асар. Икенче җилд. 15 нче җөзьә / Р. Фәхретдин. – Оренбург: Товарищество «Каримов, Хусаинов и К$^{О}$», 1908. – 79 б.

Фәхретдин Р. «Шура»ның тел ярышы. / Р. Фәхретдин – Оренбург: Вакт, 1910, 195 б.

Фәхретдин Р. Нәсыйхәт. Өченче: Олуглар вә бөекләр өчен. «Гыйлем әхлак»дан тукызынчы җөзьә / Р. Фәхретдин. – Оренбург. Дүртенче табгы. – Казан: Электро-тип. «Миллят», 1911. – 40 б.

Фәхретдин Р. Җәвамигуль-кәлим шәрхе: Гарәби-урыс хоруфатында беренче басма / Р. Фәхретдин. – Казан: Иман, 1416 / 1995. – 605 б.

Халидов Ф. Рәдде бичара кыз: Драма. Өч фасыл, биш действия / Ф. Халидов. Казан: тип. Г. М Вячеслава, 1888. – 21 б.

Халиди Ф. Әлфе сәхәр вә сәхәр: өч кисәк / Ф. Халидов. – Казан, 1903 – 1 нче китаб. – 263 б.; 2 нче китаб. – 203 б.; 1904. – 3 нче китаб. – 228 б.

Хальфин С. Русско-татарский словарь: в 2-х томах / С. Хальфин. – Казань, 1785.

Хорезми. Мухаббат-наме / издание текста, транскрипция, перевод и исследование Э.Н. Наджипа. – М.: Изд.восточной лит-ры, 1961. – 223 с.

Хөсәенов М.З. Тәварихы Болгария / М.З. Хөсәенов. – Казан, 1883. – 60 б.

Хөснетдинов Р. «Шура»ның «Тел ярышы». Транскрипция: хрестоматия / Р. Хөснетдинов. – Казан: КМТТУ нәшрияты, 2015. – 164 б.

Чокрый Г. Китабы шәмгъ әз-зыя фи тәзәкүрәти кауме әһле әз-зыя / Г. Чокрый. – Казан: Г.М. Вячеслав табгыханәсе. Мөхәммәтзарыйф Әхмәтҗан угылы хәрежәте белән, 1883. – 40 б.

Чокрый Гали. Замма назыйр китабы (Заман ахыры бәйанында) / Гали Чокрый. – Казан: Электро-тип. «Үрнәк» (елы күрсәтелмәгән).

Языки мира. Тюркские языки. – Бишкек, 1997. – 542 с.

Ялчыгол Таҗеддин. Китабе Рисаләи Газизә: Шәрхе «Сөбател гаҗизин». – Казан: Ун-т табгыханәсе, 1850. – 440 б.

Ялчыгол Таҗеддин. Рисаләи Газизә / әсәрне басмага әзерләүче, гарәп графикасындагы текстларны укып, басмалар арасындагы аермалыкларны күрсәтеп, гамәлдәге язуга күчерүче, аңлашылмый торган сүз-гыйбарәләрне һәм юлларны тәрҗемә итүче, тиешле шәрехләр бирүче Хатыйп Йосыф угылы Миңнегулов. – Казан: Иман, 2001. – I т. – 240 б.; II т. – 241 – 480.

Янбаева Я.С. Каталог старотатарских книг в Российской Академии наук (1802–1931). – Иерусалим, 2010. – 284 с.

Яхин Т. Тәгълим әл-әдәб-иләл вәлад / Т. Яхин. – Казан: Тип. ун-та, 1898. – 38 б.

Яхин Т. Сабый вә сабыялар өчен мәргүб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олугларны тәнбиһ өчен гаҗәйеб булган гыйбрәтләр / Т. Яхин. – Казан: Тип. ун-та, 1897, 1902. – 112 б.

XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия / төзүче, искәрмәләр һәм аңлатмаларны әзерләүче Марсель Әхмәтҗанов. – Казан: Дом печати, 2006. – 363 б.

XVIII йөз татар әдәбияты: Проза / төз. Марсель Әхмәтҗанов; җав. ред. Зөфәр Рәмиев. – Казан: Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институты, 2012. – 444 б .

A Fourteenth century turkic translatijn of Sa`dis Culistan (Sayfi Sarayis Culistan bit-turki). By A. Bodrogligeti. – Budapest, 1969. – 450 p.

Eckmann J. Nehcü'l-Feradis. I, Tipki Basim. – Ankara, 1956. – 444 s.

Kısasül Enbıya. I / Giriş Metin Tıpkı basım. Dr. Aysu Ata. – Ankara. 1997. – 616 с.

Zajaczkowski A. Slownik Arabsko-Kipczacki z okresu Panstwa Mameluckiego Bulgat al-Muştaq fi lugat at-turk wa-l-Qifzaq / A. Zajaczkowski. – Warszawa, 1954. – 86 s.

**Фәнни-теоретик әдәбият**

Абдуллин И.А. Армяно-кыпчакские рукописи и их отношение к диалектам татарского языка / И.А. Абдуллин // Материалы по татарской диалектологии: сб. ст. – Казань, 1974. – С. 175–176.

Абдуллин И.А. Әдәби тел тарихын һәм чыганаклар өйрәнүнең төп концепцияләре / И.А. Абдуллин // Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка. – Казань, 1992. – С. 8–20.

Абдуллин Я. Ислам безнең тарихыбызда һәм әдәбиятыбызда / Я. Абдуллин // Казан утлары. – 1993. – № 7. – Б. 169.

Абдуллина Р.С. Татар телендә синтетик үткән заманнарның формаль үзенчәлекләре һәм семантик кулланылышы / Р.С. Абдуллина // Очерки по морфологии татарского глагола. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. – Б. 84–99.

Абдуллина Р.С. Развитие значений и стилистические особенности временных форм татарского глагола: автореф. дис. ... канд. филол. наук. / Р.С. Абдуллина. – Казань, 1988. – 18 с.

Абдулхаков Р.Р. Языковые особенности произведений Мусы Джаруллаха Бигиева: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Р.Р. Абдулхаков. – Казань, 2007. – 24 с.

Абдулхаков Р.Р. Языковые особенности произведений Мусы Джаруллуха Бигиева / Р.Р. Абдулхаков. – Казань: РИИ, 2010. – 224 с.

Абилов Ш.Ш. «Кутадгу билиг» в булгаро-татарской литературе / Ш.Ш. Абилов // Советская тюркология. – 1970. – № 6. – С. 77–97.

Абилов Ш.Ш. О новонайденных списках памятника XIV века «Нахдж ал-Фарадис» / Ш.Ш. Абилов // Советская тюркология. – 1977. – № 2. – С. 69–73.

Абилов Ш.Ш. «Җәмигыт-тәварих» // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – I т. Урта гасырлар дәвере. – 567 б.

Авхадиев И.Ш. Арабско-тюркский словарь XVI века / И.Ш. Авхадиев // Вопросы татарского языкознания. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1965. – Кн. 2. – С. 343–357.

Адыгамов Р.К. Габдрахим Утыз-Имяни / Р.К. Адыгамов. – Казань: Фэн, 2005. – 234 с.

Айда Адилә. Садрый Максуди Арсал / Адилә Айда. – Анкара: Культур Баканлыг, 1991. – 290 б.

Айдаров Г. Язык орхонских памятников древнетюркской письменности VIII века / Г. Айдаров. – Алма-Ата: Наука, 1971. – 380 с.

Алеева А.Х. Путешествие Исмагил ага в Индию: исследование языка татарских путевых записок XVIII в. «Исмагил ага сәяхәтнамәсе» / А.Х. Алеева. – Казань, 1993. – 166 с.

Алексеев А.А. Пути стабилизации языковых норм в России X– VI веков / А.А. Алексеев // Вопросы языкознания. – 1987. – № 2. – С. 34–36.

Алмаз Дж. «Кысса-и Йусуф» Кул Гали – памятник булгаро-татарской литературы / Дж. Алмаз // Поэт-гуманист Кул Гали: материалы юбилейных торжеств и научной конференции, посвященных 800-летию со дня рождения и 750-летию его поэмы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – С. 225–255.

Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр / Г. Алпаров. – Казан, 1945.

Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр / Г. Алпаров. – Казан: Мәгариф, 2008. – 287 б.

Аль-Аммари Мохаммед Салех. Синтаксис арабского языка (с углубленным изучением истории и культуры ислама) [Электронный ресурс]: учебное пособие. – Казань: Изд-во ДУМ РТ, 2009 – 221 с. URL: http://znanium.com/catalog.php?bookinfo=53851

Амирханов Р.М. Татарская социально-философская мысль Средневековья (XIII – середина XVI вв.) в 2-х кн. / Р.М. Амирханов. – Казань, 1993. – 2 кн. – 111 с.

Ахатов Г.Х. Диалект западносибирских татар / Г.Х. Ахатов. – Уфа: Изд-во БГУ, 1963. – 195 с.

Ахатов Г.Х. Татарская диалектология. Средний диалект: (учеб. пособие) / Г.Х. Ахатов. – Уфа: Изд-во БГУ, 1979. – 80 с.

Ахатов Г.Х. Мишарский диалект татарского языка: (учеб. пособие) / Г.Х. Ахатов. – Уфа: Изд-во БГУ, 1980. – 82 с.

Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов / О.С. Ахманова. – 1969. – 608 с.

Ахметгалиева Я.С. Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы» / Я.С. Ахметгалиева. – М. : Наука, 1979. – 191 с.

Ахметгалеева Я.С. Архив Р. Фахрутдинова в Ленинградском отделении Института востоковедения АН СССР / Я.С. Ахметгалеева // Исследования по лексике и грамматике татарского языка. – Казань, 1986. – С. 132–146.

Ахметзянов М.И. О лексике эпитафий XVII–XVIII вв / М.И. Ахметзянов // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников: сб. ст. – Казань, 1983. – С. 75 – 84.

Ахметзянов М.И. Новые археографические материалы и их значение в исследованиях по истории татарской литературы: автореф. дис. ... д-ра филол. наук / М.И. Ахметзянов. – Казань, 1998. – 67 с.

Ахметьянов Р.Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья / Р.Г. Ахметьянов. – М.: Наука, 1981. – 143 с.

Әмирхан Р. Г. Иманга тугрылык / Р.Г. Әмирханов. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1997. – 384 б.

Әхмәтҗанов М.И. Яңа археологик табышлар һәм аларны татар әдәбияты тарихын тикшерүдә куллану: филол. фән. д-ры ... дис. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан, 1998. – 421б.

Әхмәтҗанов М. И. Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы / М. Әхмәтҗанов. – Казан: Мәгариф, 1999. – 159 б.

Әхмәтҗанов М.И. Татар кульязма китабы / М. И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 270 б.

Әхмәтҗанов М. Хәсән Кайгы. Казтуган. Дусмәмбәт. Чалгиз жырау // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – II т. – Б. 44–71.

Әхмәтҗанов М. Казан ханлыгы чоры (XV–XVI гасырлар) татар әдәбияты. Тарихи-документаль ядкярләр / Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – II т. – Б. 25–31.

Әхмәтьянов Р. Иҗатының башлангыч чорында Мәҗит Гафури хезмәтләренең теле / Р. Әхмәтҗанов // Маджит Гафури: материалы научной конференции. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. – 115 б.

Бакиров М.Х. Генезис и древнейшие формы общетюркской поэзии: автореф. дис. ... д-ра филол. наук / М.Х. Бакиров. – Казань, 1999. – 96 с.

Баскаков Н.А. Ногайский язык и его диалекты / Н.А. Баскаков. – М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1940. – 272 с.

Баскаков Н.А. Каракалпакский язык. Фонетика и морфология (части речи и словообразование): в 2 т. / Н.А. Баскаков. – М.: Изд-во АН СССР, 1952. – Т. II. – Ч. 1. – 543 с.

Баскаков Н.А. Роль уйгуро-карлукского литературного языка караханидского государства в развитии литературных тюркских языков средневековья / Н.А. Баскаков // Советская тюркология. – 1970. – № 4. – С. 13–19.

Баширова И.Б. На путях демократизации литературного языка: морфологические категории в произведениях Фатиха Амирхана / И.Б. Баширова // Истоки татарского литературного языка. – Казан, 1988. – С. 112–116.

Баширова И.Б. Устойчивые общие нормы и индивидуальные особенности в языке татарской XVдожественной прозы начала XX века / И.Б. Баширова // Формирование татарского языка. – Казань, 1989. – С. 45–50.

Баширова И.Б. Язык Художественной прозы Г. Исхаки / И.Б. Баширова // Язык утилитарных и поэтических жанров памятников татарской письменности. – Казань, 1990. – С. 132–139.

Баширова И.Б. Татарский литературный язык конца XIX – начала XXвека: литературная норма, вариативнось нормы и функционально-стилистическая вариативность в категориях имени существительного и наклонениях глагола: автореф. дис. ... д-ра филол. наук / И.Б. Баширова. – Казань, 2000. – 68 с.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби теле: жанр-стильләре, аерым грамматик категорияләрдә норма һәм вариантлылык / И.Б. Баширова. – Казан: ТӘһСИ, 2008. – 340 б.

Баширова И.Б. История татарского литературного языка: письменнотрадиционная норма и вариативность / И.Б. Баширова // Научный

Татарстан: Гуманитарные науки. Тюркология. – Казань, 2009. – № 4. – С. 50–54.

Баширова И.Б. Изучение истории татарского литературного языка в ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова: состояние и перспективы (И.Б. Баширова, Р.Ф. Мирхаев // Поиски и открытия. Роль научно-исследовательских институтов в становлении гуманитарного знания. – Казань, 2015. – С. 19–23.

Бәдигъ Х. Татар әдәби теленең барышы / Хуҗа Бәдигый: тел галиме, фольклорчы, педагог. – Казан, 2008. – Б. 157–189.

Бәширова И.Б. Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле: татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире (VIII–X класслар өчен әдәбияттан кулланма) / И.Б. Бәширова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 96 б.

Бәширова И.Б., Хаков В.Х. Әдәби тел һәм матур әдәбият стиле // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – 2 том: XIX йөз татар әдәбияты / И.Б. Бәширова, В.Х. Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – Б. 514–541.

Бәширова И.Б. Фатих Әмирхан прозасының стиль үзенчәлекләре / И.Б. Бәширова // Идейно-эстетическое наследие Фатиха Амирхана. Межвузовский сборник научных трудов. – Казань, 1989. – Б. 141–146.

Бәширова И.Б. Әдәби норма һәм вариантлылык (XIX йөз ахыры – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова // Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка. – Казань, 1992. – Б. 59–66.

Бәширова И.Б. XX гасыр башы татар әдәби теле һәм аны өйрәнү ысулларына карата / И.Б. Бәширова // Төркиләрнең телләре, рухи мәдәниятләре һәм тарихлары: традицияләр һәм заман. – Казань, 1992. – I т. – Б. 141–144.

Бәширова И.Б. Муса Акъегетзадә татар әдибеме? / И.Б. Бәширова // Мәдәни җомга. – 1997. – 22 август.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби телен өйрәнүнең кайбер нәтиҗәләре / И.Б. Бәширова // Гыйльми язмалар, ТДГИ. – Казан, 1997. – № 2. – Б. 122–131.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле һәм Г. Исхакый иҗаты / И.Б. Бәширова // Гыйльми язмалар, ТДГИ. – Казан, 1998. – № 3. – Б. 63–68.

Бәширова И.Б. Ризаэддин Фәхретдинев һәм татар әдәби теле / И.Б. Бәширова // Гыйльми язмалар, ТДГИ. – Казан, 1998. – № 4. – Б. 79–93.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле һәм Фатих Кәрими иҗаты / И.Б. Бәширова // Общественное развитие и гуманитарные науки. ТГГИ. Гыйльми язмалар. Вып. 6. – Казань, 1999. – Б. 43–47.

Бәширова И.Б. Татар әдәби теле тарихы: XIX гасыр ахыры – XX йөз башы.... / И.Б. Бәширова. – Казань: КДТУ нәшр., 1999. – 576 б.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле һәм Г. Исхакый иҗаты / И.Б. Бәширова // Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы. – Казань: Фикер, 2000. – Б. 256–267.

Бәширова И.Б. Хәзерге татар әдәби телендә фәнни әдәбият стиле / И.Б. Бәширова // Фән һәм тел. – 2000. – № 3. – Б. 12–16.

Бәширова И.Б. Татар филологиясендә язма әдәби тел теориясе / И.Б. Бәширова // Языковые уровни и их анализ. – Казань: Изд-во ТГГИ, 2001. – Б. 49–65.

Бәширова И.Б. «Нур» газетасында язма әдәби тел мәсъәләсе / И.Б. Бәширова, Ф. Мөхәммәтшин // КДУ: Фәнни язмалар. 2001. – Казан: Школа, 2002. – Б. 12–17.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле һәм Г. Ибраһимов иҗаты / И.Б. Бәширова // Г. Ибраһимов һәм хәзерге заман. – Казан: Фикер, 2003. – Б. 193–204.

Бәширова И.Б. Татар әдәби теле һәм Ризаэддин Фәхретдинев иҗаты / И.Б. Бәширова // Р. Фәхретдин. Мирасы һәм хәзерге заман: фәнни конф. материаллары. – Казан, 16 ноябрь, 1999. – Казан, 2003. – Б. 206–218.

Бәширова И.Б. Латыйф Җәләй һәм татар стилистиксының өйрәнелә башлавы / И.Б. Бәширова // Актуальные вопросы татарского языкознания. – Вып. 4. К 110-летию Л. Заляя. – Казань, 2005. – Б. 39 – 48.

Бәширова И.Б. Тел берәмлекләрен Тел һәм Сөйләм күренеше буларак өйрәнгәндә терминнарны аерымлау / И.Б. Бәширова // Фән һәм тел, 2005. – № 3.

Бәширова И.Б. Әдәбият текстологиясендә лингвистик аспект / И.Б. Бәширова // Татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре: урта гасырлар – XX йөз башы. – Казан, 2006. – Б. 111–120.

Бәширова И.Б. Җамал Вәлиди һәм татар әдәби теле мәсьәләләре / И.Б. Бәширова // Җамал Вәлиди – энциклопедист галим: республика фәнни-гамәли конф. материаллары. – Казан, 2007. – Б. 85–103.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле һәм Акмулла иҗаты / И.Б. Бәширова // Акмулла һәм хәзерге заман: мәкаләләр җыентыгы. – Казан, 2007. – Б. 178–190.

Бәширова И.Б. Суфиян Поварисовның Г. Ибраһимов турындагы трилогиясе: авторның сәнгатьле сөйләм үзенчәлеге / И.Б. Бәширова // Г. Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2007. – Б. 187–190.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: жанр-стильләре, аерым грамматик категорияләрдә норма һәм вариантлылык / И.Б. Бәширова. – Казан: Алма-Лит, 2008. – 340 б.

Бәширова И.Б. Татар әдәби теле. Семасиология / И.Б. Бәширова. – Казан, 2010. – 532 б.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле һәм Г. Тукайның башлангыч чор иҗаты / И.Б. Бәширова // Г. Тукай мирасы һәм милли-мәдәни бәйләнешләр. – Казан, 2011. – Б. 207–210.

Бәширова И.Б. Татар әдәби теле тарихы. Гомумтеоретик мәсьәләләр: Татар теленең билге-шартлары һәм аларның өйрәнелеше / И.Б. Бәширова. – Казан, 2012. – 255 б.

Бәширова И.Б. Иске татар теле – гомумтөркигә нигезләнгән региональ язма әдәби тел / И.Б. Бәширова // Төрки халыклар әдәбияты һәм сәнгате Шәрекъ һәм Гареб мәдәнияты контекстында. – Казан, 2014. – Б. 108–112.

Бәширова И.Б. Тукай төрек телендә шигырь язганмы? // Казан утлары. – 2015. – Б. 110–120.

Бәширова И.Б.  Г. Кандалый иҗаты – татар әдәби теле тарихының сагышлы бер дәвере / И.Б. Бәширова // Г. Кандалый: через призму современности. – Казань: ИЯЛИ, 2015. – Б. 96–114.

Бәширова И.Б. Кереш. Фән буларак татар язма әдәби теле тарихы: теоретик мәсьәләләр / И.Б. Бәширова // Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). 1 том. Фонетика. Графика: язма традицияләр... – Казан, 2015. – Б. 8–232.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар сәнгатьле прозасында хикәяләү стильләре / И.Б. Бәширова // Фәнни Татарстан. – 2016. – № 1. – Б. 9–14.

Бәширова И.Б. Иске татар теле: Г. Тукайның башлангыч чор иҗаты / И.Б. Бәширова // Г. Тукай и тюркский мир. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – Б. 74–82.

Бәширова И.Б. Идел буе төркисе – иске татар телендә язма норма мәсьәләсенә карата / И.Б. Бәширова // Татарское языкознание в контексте Евразийской гуманитарной науки. – Казань, 2016. – Б. 56–64.

Бәширова И.Б. Төрки-татар язма әдәби теле нәзарияте: Фатих Әмирхан иҗаты / И.Б. Бәширова // Фәнни Татарстан. 2017. – Б. 7–19.

Бәширова И.Б. Төрки-татар язма әдәби теле нәзарияте: Галимҗан Ибраһимов иҗаты / И.Б. Бәширова // Наследие Галимджана Ибрагимова в контексте многообразия культур: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Ибрагимова. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – С. 26–34.

Березин Ф. М., Головин Б. И. Общее языкознание / Ф. М. Березин, Б. И. Головин. – М.: Просвещение, 1979. – 415 с.

Благова Г.Ф. Некоторые вопросы развития средневекового среднеазиатского литературного языка / Г.Ф.Благова // Советская тюркология. – 1971. – № 7. – С.68–75.

Благова Г.Ф. О соотношениях прозаического и поэтического варианта среднеазиатско-тюркского литературно-письменного языка XV – нач. XIV в. / Г.Ф. Благова // TURCOLOGICA. – Л., 1976. – С. 27–37.

Благова Г.Ф. О методике изучения морфологии средневековых тюркских поэтических текстов / Г.Ф. Благова // Вопросы языкознания. – 1977. – № 3. – С. 86–100.

Благова Г.Ф. Проблемы лингвистического изучения средневековых тюркских текстов / Г.Ф.Благова // Тюркологический сборник. – М., 1977. – С. 27–50.

Благова Г.Ф. О принципах лингвистического изучения тюркских текстов / Г.Ф. Благова // Вопросы языкознания. – 1979. – № 6. – С. 97–107.

Благова Г.Ф. Тюркское склонение в ареально-историческом освещении: юго-восточный регион / Г.Ф. Благова. – М.: Наука, 1987. – 304 с.

Благова Г.Ф. Соотношение «истории литературного языка» и «исторической грамматики» / Г.Ф. Благова // Советская тюркология. – 1988. – № 1.– С. 80–85.

Благова Г.Ф. Бабур-наме. Язык, прагматика текста, стиль. К истории чагатайского литературного языка / Г.Ф. Благова. – М.: Восточная литература РАН, 1994. – 404 с.

Богородицкий А.В. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. Изд. 2-е, испр. и доп. / А.В. Богородицкий. – Казань, 1953. – 220 с.

Борынгы татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. – 525 б.

Боровков А.К. Лексика среднеазиатского тефсира XII–XIII вв. / А.К. Боровков. – М.: Изд-во вост. лит, 1963. – 367 с.

Бурганова Н.Б. Диалекты татарского языка и памятники древней письменности / Н.Б. Бурганова // Вопросы татарского языка и литературы: сб. ст. – Казань, 1969. – С. 35–40.

Бурганова Н.Б. Система глагола поэмы Мухамедьяра «Төхфәи Мәрдан» (XVI в. ) / Н.Б. Бурганова // Исследование языка древнеписьменных памятников. – Казань, 1980. – С. 66–96.

Валиди Дж. Очерк истории образованности и литературы волжских татар / Дж. Валиди. – Казань: Иман, 1998. – 157 с.

Валитова Ю.А. Иноязычные элементы в поэтических произведениях Г. Тукая (Турецко-огузские элементы и арабские масдары): автореф. дис. ... канд. филол. наук / Ю.А. Валитова. – М., 1966. – 23 с.

Вахидов С.Г. Исследование языка Сахиб-Гирей Хана / С. Г. Вахидов // ИОАИЭ. – Казань, 1925. – Т. 33.

Вәлиди Җ. Татар әдәбиятының барышы. Беренче җөзьә / Җ. Вәлиди. – Оренбург: Вактъ матбагасы, 1912. – 122 б.

Вәлиди Җ. Татар телен эшләү мәсьәләсе / Җ. Вәлиди // Сайланма хезмәтләр. – Казан, 2007. – Б. 107–145.

Вәлиди Җ. Телебезнең үсү тарихыннан / Җ. Вәлиди // Сайланма хезмәтләр. – Казан, 2007. – Б. 159–163.

Вәлиди Җ. Сайланма хезмәтләр: Әдәби тел, грамматика, диалектология һәм лексикография мәсьәләләре / Җ. Вәлиди. – Казан: Мәгариф, 2007. – 271 б.

Виноградов В.В. Проблемы литературных языков и закономерностей их образования и развития / В.В. Виноградов. М.: Наука, 1967. – 134 с.

Виноградов В.В. История русских лингвистических учений / В.В. Виноградов. – М.: Высшая школа, 1978. – 367 с.

Виноградов В.В. Очерки по истории русского литературного языка XVII–XIX веков / В.В. Виноградов. – М.: Высш. шк., 1982. – 529 с.

Волкова З. Н. Истоки французского литературного языка / З.Н. Волкова. – М.: Высшая школа, 1983. – 168 с.

Гавранек Б. Задачи литературного языка и его культура / Б. Гавранек // Пражский лингвистический кружок. – М.: Изд-во Иностр. лит., 1967. – 559 с

Гаджиева Н.З. Основные пути развития синтаксической структуры тюркских языков / Н.З. Гаджиева. – М. : Наука, 1973. – 408 с.

Гаджиева Н.З. Проблемы тюркской ареальной лингвистики / Н.З. Гаджиева. – М.: Наука, 1975. – 303с.

Гайнетдинев М.В. Литература XVIII века / М.В. Гайнетдинев / Средневековая татарская литература VIII–XVIII вв. – Казань: Фән, 1999. – С. 181–199.

Гайнетдинов М. Кадыйргали бәк. «Җәмигыт-тәварих». «Дәфтәре Чыңгызнамә» / М. Гайнетдинов // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – II т. – Б. 201–211.

Гайнетдинов М. Суфи Аллаһияр. «Сөбател-гаҗизин» / М. Гайнетдинов // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – II т. – Б. 227–233.

Гайнетдинов М. Максуди «Могҗизнамә» // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – II т. – Б. 72–94.

Гайнетдинов М.В. Идел буенда гомумтөрки әдәбият һәм Насретдин Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» әсәре / М.В. Гайнетдинов // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – I т. Борынгы чор һәм урта гасырлар. – Б. 252–280.

Гайнетдин М. Әбелмәних Каргалый / М. Гайнетдин // Ш. Зәки, Ә. Каргалый. Мөнәҗәтләр. Хикәятләр. – Казан: Иман, 2002/1423. – Б. 14–28.

Гайнетдин М. Шәмсетдин Зәки / М. Гайнетдин // Ш. Зәки, Ә. Каргалый. Мөнәҗәтләр. Хикәятләр. – Казан: Иман, 2002/1423. – Б. 3–13.

Гайнуллина Г.Ф. Морфологические особенности поэмы Кутба «Хосров и Ширин» (XIV в. )/ Г.Ф. Гайнуллина. – Казань: Казан. гос. ун-т, 2010. – 240 с.

Гайнуллина Г.Ф. Система глагола в поэме Кутба «Хосров и Ширин» (XIVв.) / Г.Ф. Гайнуллина. – Казань: Отечество, 2015. – 150 с.

Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы. I том. 2 нчебүлек / Г. Газиз, Г. Рәхим. – Казан, 1922. – 244 б.

Газиз Г. История татар / Г. Газиз. – М.: Московский лицей, 1994. – 197 с.

Гали М. Өмми Камал китабы / М. Гали // Совет әдәбияты. – 1941. – № 5. – Б. 41–63.

Галяутдинов И.Г. «Тарих намаи булгар» Таджетдина Ялсыгулова / И.Г. Галяутдинов. – Уфа: Башк. кн. изд-во, 1990. – 238 с.

Ганиева Р.К. Восточный ренессанс и поэт Кул Гали / Р.К. Ганиева. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – 170 с.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. – 854 б.

Гарданов Х.Ш. Повелительное наклонение и его стилистическое употребление в современном татарском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Х.Ш. Гарданов. – Уфа, 1969. – 25 с.

Гарипова Г.Ф. Морфологические особенности поэмы Кутба «Хосров и Ширин» (XIV в. ): дис. ... канд. филол. наук / Г.Ф. Гарипова. – Казань, 2003. – 244 с.

Гариф Н. Казан ханлыгы чоры ташъязмалары / Н. Гариф. – Казан: ТФА, Тарих институты басмаханәсе, 2010. – 128 б.

Гафури М. Чуар тел / М. Гафури // Мәҗит Гафури. Әсәрләр: дүрт томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – III том. – Б. 357–361.

Гилемшин Ф. Ф. Особенности перевода «Тысяча и одной ночи» на татарский язык (язык и стиль). – Казань: Мастер лайн, 2001. – 138 с.

Гобәйдуллин Газиз. Тарихи сәхифәләр ачылганда. Сайланма хезмәләр / Г. Гобәйдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 334 б.

Гомәров И. Мәгърифәт җырчысы: Гали Чокрыйның тормыш һәм иҗат сәхифәләре. – Казан: Школа, 2006. – 444 б.

Госманов М. Яңа табылган әдәби, тарихи, истәлекләр / М. Госманов // Казан утлары. – 1966. – № 7. – Б. 81–86.

Григорьев А.П. Официальный язык Золотой Орды XIII–XIV вв. / А.П. Григорьев // Тюркологический сборник, 1977. – М.: Наука, 1981. – С. 81–89.

Грунина Э.А. Историческая грамматика турецкого языка: (Морфология) / Э.А. Грунина. – М.: Изд-во МГУ, 1991. – 224 с.

Грунина Э.А. Вопрос о варианте нормы в изучении истории турецкого языка / Э.А. Грунина // Вестник МЖ, сер. 13, Востоковедение. – 1971. – № 3.

Грунина Э.А. К вопросу о письменной традиции в анатомийских памятниках XIII–XIV вв. / Э.А. Грунина // Советская тюркология. – 1971. – № 4. – С. 98–104.

Грунина Э.А. О «смешанном» характере языка письменных памятников, или проблема olga ~ bolga / Э.А. Грунина // Вопросы тюркской филологии. Выпуск III (Материалы Дмитриевских чтений). – М., 1997. – С. 12–21.

Грунина Э.А. Соотношение форм настоящего и будущего времени по памятникам турецкого языка XIII–XIV веков // Вопросы тюркской филологии. – М. – 1966. – С. 84–89.

Губайдуллина А.Г. Исследование языка «Сэяхетнаме» и эпистолярно-публицистических произведений Фатиха Карими (конец XIX – начало XX в. ): автореф. дис. ... канд. филол. наук / А.Г. Губайдуллина. – Казань, 2002. – 22 с.

Гузев В.Г. Очерки по теории тюркского словоизменения: Глагол (на материале староанатолийско-тюркского языка / В.Г. Гузев. – Л.: Изд-во ЛГУ, 1990. – 164.

Гузев ВГ. Староосманский язык / В. Г. Гузев. – М.: Наука, 1979. – 95 с.

Гухман М.М. Изучение регионального варьирования в немецком литературном языке и методика лингвистической географии / М.М. Гухман // Philologica. Исследования по языку и литературе. – М., 1973.

Гухман М.М. История немецкого литературного языка IX–XV вв. / М.М. Гухман, Н.Н. Семенюк. – М.,1983. – 215 с.

Гыйләҗев И. Татар грамматикаларында хикәя фигыль формаларының бирелеше (XIX йөзнең беренче яртысы) / И. Гыйләҗев // Татар теле белеме, 5 нче китап. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1972. – Б. 99–115.

Давлетшин Г.М. Духовная культура предков татарского народа (истоки, становление и развитие): дис. ... д-ра ист. наук / Г.М. Давлетшин. – Казань, 2002 . – 414 с.

Давлетшин К. Творчество татарского поэта XVII века Мавля Кулый: автореф. ... канд. филол. наук / К. Давлетшин. – Казань, 1971.

Дашчян Т.Дж. Глагольные имена на *-дыг, -ачаг, -маг* и *-ма* в современном азербайджанском литературном языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Т.Дж. Дашчян. – Баку, 1962. – 31 с.

Дәүләтшин К. Мәүла Колый хикмәтләренең поэтикасы һәм тел үзенчәлекләре // Татар теле һәм әдәбияты. – 5 чыг. – Казан, 1976. – Б. 203–214.

Дәүләтшин Г.М. Төрки-татар рухи мәдәнияты тарихы / Г.М. Дәүләтшин. – Казан, 1999. – 512 б.

Дәүләтшин К.С. Мәүлә Колый хикмәтләренең поэтикасы һәм тел үзенчәлекләре / К.С. Дәүләтшин // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан: 1976. – Б. 203–214.

Дәүләтшин К. Мәүлә Колый / К. Дәүләтшин // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. –Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – II т. – Б. 241–266.

Десницкая А.В. Наддиалектные формы устной речи и их роль в истории языка / А.В. Десницкая. – Л.: Наука, 1970. – 99 с.

Джанмавов Ю.Дж. Деепричастия в кумыкском литературном языке / Ю.Дж. Джанмавов. – М.: Наука, 1967. – 330 с.

Дмитриев Н.К. Грамматика кумыкского языка / Н.К. Дмитриев. – М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1940. – 205 с.

Дмитриев Н.К. Грамматика башкирского языка / Н.К. Дмитриев. – М. –Л.: Изд-во АН СССР, 1948. – 276 с.

Дмитриев Н.К. Турецкий язык / Н.К. Дмитриев. – М.: Изд-во вост. лит., 1960. – 96 с.

Древнетюркский словарь. – Л.: Наука, 1996. – 676 с.

Дубинин С.И. Немецкий литературный язык позднего средневековья: юго-западный ареал / С.И. Дубинин. – Самара: Изд-во Самарского ун-та, 2000. – 200 с.

Дыренкова Н.П. Грамматика ойротского языка / Н.П. Дыренкова. – М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1940. – 303 с.

Дыренкова Н.П. Грамматика шорского языка / Н.П. Дыренкова. – М. –Л.: Изд-во АН СССР, 1941. – 309 с.

Дыренкова Н.П. Грамматика хакасского языка. Фонетика и морфология / Н.П. Дыренкова. – Абакан: Хакасоблнациздат, 1948. – 124 с.

Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды XV–XVI вв. / В.Л. Егоров. – М.: Наука, 1985. – 245 с.

Едличка А. Проблематика нормы и кодификации литературного языка в отношении к типу литературного языка / А. Едличка // Проблемы нормы в славянских литературных языках в синхронном и диахронном аспектах. – М.: Наука, 1976. – 204 с.

Җәләй Л. Тукай телендә фигыльләр / Л. Җәләй // Совет әдәбияты. – Казан, 1938. – № 3. – Б. 58–66; № 4. – Б. 58–65; № 5. – Б. 69–73.

Җәләй Л. Татар диалектологиясе / Л. Җәләй. – Казан: Татгосиздат, 1947. – 131 б.

Җәләй Л. Татар әдәби теле тарихы буенча лекцияләр / Л. Җәләй. Кулъязма. – Казан, 1958.

Җәләй Л. Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар) / Л. Җәләй. – Казан: ИЯЛИ, 2000. – 288 б.

Зайнуллин Г.Г. Татарская богословская литература XVIII – начала XX веков и ее стиле-языковые особенности: дис. в виде науч. докл. ... д-ра филол. наук / Г.Г. Зайнуллин. – Казань, 1999. – 107 с.

Зайончковский А. К изучению средневековых памятников тюркской письменности (XI–XVI вв.) / А. Зайончковский // Вопросы языкознания. – 1967. – № 6. – С. 80–89.

Закиев М.З. Некоторые вопросы развития татарского литературного языка / М.З. Закиев // Вопросы языкознания: сб. ст. – Казань: Таткнигоиздат, 1965. – С. 5–37.

Закиев М.З. Взаимоотношения татарского литературного языка и диалектов в различные периоды их развития / М.З. Закиев // Лингвистическая география, диалектология и история языка. – Ереван: Изд-во АН Армянской ССР, 1976. – С. 313–318.

Закиев М.З. Проблемы языка и происхождения волжских татар / М.З. Закиев. – Казань: Таткнигоиздат, 1986. – С. 140–141.

Закиев М.З. Введение: койне, традиционные нормы, старотатарский и современный татарский литературный язык / М.З. Закиев // Истоки татарского литературного языка: сб. ст. – Казань, 1988. – С. 3–11.

Закиев М.З. Татары: проблемы истории и языка / М.З.Закиев. – Казань, 1995. – 464 с.

Закиев М.З. Тюрко-татарское письмо (история, состояние и перспективы) / М.З. Закиев. – М.: Инсан, 2005. – 248 с.

Закирова Г.К. Синонимы в языке тюрко-татарских письменных памятников периода Золотой Орды / Г.К. Закирова. – Казань: Изд-во Казан. гос. техн. ун-та, 2009. – 216 с.

Зәйниева Г.Н. Кол Мәхәммәднең шигъри иҗаты: Текстология, проблемалар һәм тел үзенчәлекләре / Г.З. Зәйниева. – Казан, 2006. – 132 б.

Зәйнуллин Җ.Г. XVIII йөз – XX йөз башында татар рухани әдәбияты: Коръән тәфсирләре, хәдисләр һ.б. чыганаклар. Тәрҗемә принциплары һәм тел үзенчәлекләре. – Казан: Мәгариф, 1998. – 207 б.

Зәкиев М.З. Төрки-татар этногенезы / М.З. Зәкиев. – Казан: Фикер; Мәскәү: Инсан, 1998. – 624 б.

Зәкиев М.З. Грамматиканың төп төшенчәләре / М.З. Зәкиев // Татар грамматикасы: өч томда. – Мәскәү: Инсан; Казан: Фикер, 1998. – I т. – Б. 152–161.

Зәкиев М.З. Татар халкы тарихы: этник тамырлары, оешуы һәм киләчәге / М.З. Зәкиев. – Казан, 2008. – 544 б.

Золотая Орда: археология, нумизматика, эпиграфика: сб. ст. – Казань, 1998. – 128 с.

Ибраһимов Г. Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре / Г. Ибраһимов. — Казан, 1924. – 143 б.

Иванов М. Татарская хрестоматия, ч. 1–2 / М. Иванов. – Казань: Типолитография ун-та, 1842. – 196 с.

Ислам в среднем Поволжье: история и современность. Очерки. – Казань: Мастер Лайн, 2001. – 516 с.

Исламов Р.Ф. «Шахнаме» Шарифа в контексте золотордынской и кипчакско-мамлюкской литератур: автореф. дис. ... д-ра филол. наук / Р.Ф. Исламов. – 2002. – 91 с.

Исламов Р. Ф. Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни багланышлар / Р.Ф. Исламов. – Казан: Фикер, 1998. – 250 б.

Исламов Р.Ф. Мәмлүкләр әдәбияты һәм «Төрки Шаһнамә» / Р.Ф. Исламов // Татар әдәбияты тарихы. Сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – I том. Борынгы чор һәм урта гасырлар. – Б. 379–392.

Исламова А.И. Исследование языка тюрко-татарского памятника XIV века «Дастан-и Джумджума Султан» Хисама Кятиба: дис.... канд. филол. наук / А.И. Исламова. – Казань, 1998. – 223 с.

Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань: ИЯЛИ, 1983. – 163 с.

Исследования по исторической диалектологии татарского языка: сб. ст. – Казань, 1979. – 176 с.

Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков: в 4-х т. – М.: Изд-во АН СССР, 1956. – Т.2.

Исследования по татарскому языку: сб. ст. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. – 158 с.

История татарского литературного языка (XIII – первая четверть XX в.) / составитель и ответственный редактор Х. Курбатов. – Казань: Фикер, 2003. – 656 с.

Исхаков Д.М. Ключевой этап татарской истории / Д.М. Исхаков // Татарстан. – 1997. – № 3. – С. 14–19.

Исхаков Д.М. Этнополитическая история татар / Д.М. Исхаков // Идель. – 1997. – № 1. – С. 36–43.

Исхаков Д. Кол-Шәриф // Идел. – 1998. – № 10. – Б. 6–8.

Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Этнополитическая история татар в VI – первой четверти XV в. / Д.М. Исхаков, И.Л. Измайлов. – Казань, 2000. – 136 с.

Исхакова А.Р. «Кысас ал-анбия» Насреддина Рабгузи. – Казань, 2005. – 180 с.

Кадирова Э.Х. Язык хикметов татарского поэта XVII века М. Кулыя / Э.Х. Кадирова. – Казань: Гуманитария, 2003. – 112 с.

Кадирова Э.Х., Бурганова Н.Б. О структуре поэм Мухаммедьяра // История татарского литературного языка (XIII – первая четверть XX в.). Казань, 2003. С. 371–407.

Кадирова Э.Х. XVI гасыр истәлеге – Коръән тәфсире хакында // Тюркоязычная книга: наследие веков: материалы Международной научно-практической кон-ции, посвящ. истории тюркоязычной книги (Казань, 17–18 октября 2012 г.). – Казань, 2012. – С. 303–306.

Кадырова Э.Х. Поэмы Мухаммедьяра «Тухфа-и мардан» и «Нур-и содур». Лексика / Э.Х. Кадырова. – Казань: Фикер, 2001. – 232 с.

Катанов Н. Ф. Материалы к изучению казанско-татарского наречия. Образцы книжной и устной литературы казанских татар: ч. 1–2 / Н.Ф. Катанов. – Казань: Тип. ун-та, 1898.

Кемаль Якуб Тюрко-татарская рукопись XIV в. «Нахжд-уль-Ферадис» / Я. Кемаль. – Симферополь: Крымское гос. изд-во, 1930. – 54с.

Кол Шәриф. И күңел, бу дөньядыр… – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 94 б.

Кондратьев В.Г. Грамматической строй языка памятников древнетюркской письменности VIII–XI вв. / В.Г. Кондратьев. – Л.: Изд-во ЛГУ, 1981. – 191 с.

Кононов А.Н. Грамматика современного турецкого литературного языка / А.Н. Кононов. – М. –Л. : Изд-во АН СССР, 1956. – 569 с.

Кононов А. Н. Грамматика современного узбекского литературного языка / А. Н. Кононов. – М. –Л. : Изд-во АН СССР, 1960. – 446 с.

Кононов А.Н. Грамматика языка тюркских рунических памятников VII–IX вв. / А.Н. Кононов. – Л.: Наука, 1980. – 243 с.

Кононов А.Н. История изучения тюркских языков в России. Дооктябрьский период / А.Н. Кононов. – Л.: Наука, 1982. – 360 с.

Котб. Хөсрәү вә Ширин / Котб. – Казан: Мәгариф. – 2003. – 367 б.

Кормушин И. В. Тюркские енисейские эпитафии: грамматика, текстология / И. В. Кормушин. – М.: Наука, 2008. – 342 с.

Краубаева А. Идейно-художественные особенности «Кыссаи Рабгузи» и «Мухаббат-наме»: автореф. дис. ... канд. филол. наук / А. Краубаева. – Алма-Ата, 1974. – 28 с.

Кузьмина Х.Х. Лексико-семантические и стилистические особенности поэмы XIII в. «Кысса и Йусуф» Кул Гали: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Х.Х. Кузьмина; Казан. гос. ун-т. – Казань, 1998. – 20 с.

Кукляшев С. Татарская хрестоматия / С. Кукляшев. – Казань: Типфия ун-та, 1859.

Курбатов Х.Р. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы / Х.Р. Курбатов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 139 б.. сх., рәс. белән.

Курбатов Х.Р. Иске татар поэзиясендә тел, стиль, метрика һәм строфика / Х.Р. Курбатов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 163 б.

Курбатов Х.Р. Тексты – основа к изучению истории литературного языка / Х.Р. Курбатов // Анализы текстов по истории татарского литературного языка. – Казан, 1987. – С. 3–5.

Курбатов Х. Р. Языковые особенности при атрибуции литературных памятников / Х.Р.Курбатов // Истоки татарского литературного языка: сб. ст. – Казань, 1988. – С. 117–125.

Курбатов Х.Р. Некоторые итоги и дальнейшие задачи изучения татарского литературного языка / Х.Р. Курбатов // Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка. – Казань, 1992. – С. 20–25.

Курышжанов А.К., Репин Б.И. К истории изучения языка древнекыпчакских памятников XIII–XVII вв. / А.К. Курышжанов // Известия АН Казахской ССР. Серия общественная. – Алма-Ата, 1966. – № 4. – С. 38–39.

Курышжанов А. К. Исследование по лексике старокыпчакского письменного памятника XIII века «Тюркско-арабского словаря» / А.К. Курышжанов. – Алма-Ата, 1970. – 233 с.

Максудова З. Онытылган шагыйрьләребез / З. Максудова // Казан утлары. – 1968. – № 1. – 97 б.

Малов Н.М. Религия в Золотой Орде: учеб. пособие для студентов ист. фак. / Н.М. Малов, А.Б. Малышев. А.И. Ракушкин. – Саратов: Изд-во Саратов. ун-та, 1998. – 127 с.

Малов С.Е. К истории и критике Codex Cumanicus / С.Е. Малов // «Известия АН СССР», 7 сер. – М., 1930. – № 5. – С. 347–375.

Малов С.Е. Мусульманские сказания о пророках по Рабгузи / С.Е. Малов // Записки Коллегии Востоковедов. – Т.I. (В честь ак. Крачковского). – Л., 1930. – С. 521–530.

Маннапова А. . Язык татарской деловой письменности XVII (истоки и традиции): автореф. дис. ... канд. филол. н. / А.Х. Маннапова. – Казань, 1982. – 21 с.

Махмутова Л.Т. Опыт исследования тюркских диалектов. Мишарский диалект татарского языка / Л.Т. Махмутова. – М.: Наука, 1978. – 271 с.

Махмутова Л.Т. Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику «Codex cumanicus» по данным лексики / Л.Т. Махмутова // Исследования по исторической диалектологии. – Вып. 2. – Казань, 1982. – С. 8–153.

Мәхмутов М.И. Татар әдәби теленә кергән гарәп-фарсы элементлары (грамматик белешмә) / М.И. Мәхмүтов // Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. – 853 б.

Мелиоранский П.М. Араб филолог о турецком языке / П.М. Мелиоранский. – СПб., 1900. – 85 с.

Миннегулов Х.Ю. Переводы и оригинальные произведения Саифа Сараи: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Х.Ю. Миннегулов; Казан. гос. ун-т. – Казань, 1972. – 31 с.

Миннегулов Х.Ю. Литература Золотой Орды / Х.Ю. Миннегулов // Татарстан. – 1992. – № 7–8. – С. 65–67.

Миннегулов Х. Ю. Татарская литература и восточная классика / Х.Ю. Миннегулов. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993. – 384 с.

Миннуллин Б.К. Татарская газета «Борхане таракки». Лингвистические исследования / Б.К. Миннуллин. – Казань: ИЯЛИ, 2012. – 300 с.

Миңнегулов Х.Й. Алтын Урда чоры язма мәдәнияте / Х.Й. Миңнегулов // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – I том. Борынгы чор һәм урта гасырлар. – Б. 240–252.

Миңнегулов Х.Й. «Кисекбаш китабы» / Х.Й. Миңнегулов // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – I том. Борынгы чор һәм урта гасырлар. – Б. 240–252.

Миңнегулов Х.Й. Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» әсәре / Х.Й. Миңнегулов //Татар әдәбияты тарих: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – I том. Борынгы чор һәм урта гасырлар. – Б. 292–300.

Миңнегулов Х.Й. Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты / Х.Й. Миңнегулов. – Казан, 1976. – 180 б.

Миңнегулов Х.Й. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар / Х.Й. Миннегулов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1988. – 198 б.

Миңнегулов Х.Й. Алтын Урда әдәбияты / Х.Й. Миңнегулов // Татарстан. – 1992. – № 7–8. – Б. 63–73.

Миңнегулов Х.Й. Алтын Урда чоры язма мәдәнияте / Х.Й. Миңнегулов // Мирас. – 1993. – № 6. – Б. 14–24.

Миңнегулов Х.Й. Урта гасыр әдәбиятын өйрәнү юлында / Х.Й. Миңнегулов // Мирас. – 1995. – № 7–8. – Б. 40–48.

Миңнегулов Х.Й. «Ни белгәйләр сине сүзләтмәсәң тел» (Алтын Урда әдәби традицияләре) / Х.Й. Миңнегулов // Мирас. – 1996. – № 5–6. – Б. 202–215.

Миңнегулов Х.Й. Татарларда ислам дине / Х.Й. Миңнегулов // Мирас. – 1998. – № 4. – Б. 109–115.

Миңнегулов Х.Й. Дөньяда сүземез бар… / Х.Й. Миңнегулов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 336 б.

Миңнегулов Х.Й. Гасырлар өнен тыңлап… / Х.Й. Миңнегулов. – Казан: Мәгариф, 2003. – 335 б.

Миңнуллин Б.К. XXгасыр башы татар газетасында мәгълүмати жанрлар / Б.К. Миңнуллин // Фәнни Татарстан, 2016. – Б. 17–20.

Мирзакаримова У. Морфологические особенности «Киссаи Рабгузи»: автореф. дис. ... канд. филол. наук / У. Мирзакаримова. – Ташкент, 1969. – 39 с.

Мирхаев Р.Ф. Огузо-турецкие элементы в татарском литературном языке конца XIX – начала XX века: дис. …канд. филол. наук / Р. Ф. Мирхаев. – Казань, 2003. – 167 с.

Мирхаев Р. Ф. Огузско-турецкий компонент татарского литературного языка (конец XIX – началоXX в. ) / Р. Ф. Мирхаев. – Казань, 2007. – 208 с.

Мирхаев Р.Ф. К вопросу исследования языка татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX в. / Р.Ф. Мирхаев // Төрки халыклар әдәбияты һәм сәнгате Шәрекъ һәм Гареб мәдәнияте контекстында. – Казан, 2014. – Б. 342–346.

Мирхәев Р.Ф. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теленең язма вариантлары / Р.Ф. Мирхаев // Фән һәм Тел, 2006. – Б. 5–9.

Мирхәев Р.Ф. Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә матур әдәбият һәм публицистик катламнар нисбәте / Р.Ф. Мирхәев // Фәнни Татарстан. – 2015. – № 1. – Б. 28–32.

Мирхәев Р.Ф. Татар язуы тарихыннан / Р.Ф. Мирхәев // Фәнни Татарстан. – 2015. – № 4. – Б. 25–30.

Мифтахова И.Г. Развитие грамматической теории в татарском языкознании: Самостоятельные части речи (По татарским грамматикам XIX – начала XX вв. ): автореф. дис.... канд. филол. наук. – Казань, 1998. – 29 с.

Мөстәкыймов И. Сәхиб-Гәрәй хан ярлыгы / И. Мөстәкыймов // Гасырлар авазы, 2003. – № 3–4. – Б. 18–21.

Мөхәммәдиев М.Г. XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар прозасында кайбер заман формаларының кулланылышы / М. Г. Мөхәммәдиев // Лексика и стилистика татарского языка. – Казань, 1982. – С. 32–38.

Мөхәммәдиев М.Г. Шәриф Камал прозасының теле / М.Г. Мөхәммәдиев. – Казан, 1991. – 135 б.

Мөхәммәтов Х. Язма әдәбият/ Х. Мөхәммәтов // Борынгы татар әдәбияты. – Казан, 1963. — 182 б.

Мусаев К.М. Грамматика караимского языка. Фонетика и морфология / К.М. Мусаев. – М. : Наука, 1964. – 344 с.

Мустакимов И.А. Замечания к чтению и интерпретации ярлыка хана Ибрагима // Актуальные проблемы истории и культуры татарского народа: Материалы к учебным курсам: в честь юбилея академика АН РТ М.А. Усманова. – Казань: Изд-во МОиН РТ, 2010. – С. 155–180.

Мустакимов И.А. Еще раз о Казанском ярлыке хана Сахиб-Гирея // Средневековые тюрко-татарские государства. Сборник статей. Вып. 5:

Вопросы источниковедения и историография истории средневековых тюрко-татарских государств. – Казань: Инс-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2013. – С. 31–47.

Мухаммедова З.Б. Исследования по истории туркменского языка XI–XIV вв. / З.Б. Мухаммедова. – Ашхабад, 1973. – 236 с.

Мухаметрахимова Р.З. Язык поэтических произведений Утыз-Имени (к истории татарского литературного языка конца XVIII – нач. XIX в.): дис. ... канд. филол. наук / Р.З. Мухаметрахимова. – Казань, 1990. – 208 с.

Наджип Э. Н. Современный уйгурский язык / Э.Н. Наджип. – М.: Изд-во вост. лит. , 1960. – 133 с.

Наджип Э.Н. Кипчакско-огузский литературный язык мамлюкского Египта XIV века: автореф. дис. . . . д-ра филол. наук / Э.Н. Наджип. – М., 1965. – 94 с.

Наджип Э.Н. «Хосров и Ширин» Кутба и его язык / Э.Н. Наджип // Тюркологический сборник. – М., 1966. – С. 80–91.

Наджип Э.Н. О средневековых литературных традициях и смешанных письменных тюркских языках / Э.Н. Наджип // Советская тюркология. – 1970. – № 1. – С. 87–92.

Наджип Э.Н. О некоторых недостатках в изучении истории тюркских языков / Э.Н. Наджип // Советская тюркология. – 1970. – № 6. – С. 48–55.

Наджип Э.Н. О памятнике XIV в. «Нахдж ал-Фарадис» и его язык / Э.Н.Наджип // Советская тюркология. – 1971. – № 6. – С. 56–89.

Наджип Э.Н. Тюркоязычный памятник XIV века «Гулистан» Сейфа Сараи и его язык. Ч. I / Э.Н. Наджип. – Алма-Ата: Изд-во АН Каз. ССР, 1975. – 210 с.

Наджип Э.Н. Историко-сравнительный словарь тюркских языков XIV века на материале «Хосров и Ширин» Кутба: в 4-х кн. / Э.Н. Наджип. – М.: Главная редакция вост. лит., 1979. – 2 кн. – 479 с.

Наджип Э.Н. Исследование по истории тюркских языков XI–XIV вв. / Э.Н. Наджип. – М.: Наука, 1989. – 291 с.

Напольнова Е.М. История турецкого литературного языка XIII–XIV вв.: дис. ... канд. филол. наук / Е.М. Напольнова. – М., 1995. – 145 с.

Насилов В.М. Язык орхоно-енисейских памятников / В.М. Насилов. – М.: Изд-во вост. лит., 1960. – 87 с.

Насилов В.М. Древнеуйгурский язык / В.М. Насилов. – М. : Изд-во вост. лит., 1963. – 122 с.

Насилов Д.М. О лингвистическом изучении памятников тюркской письменности / Д.М. Насилов // Тюркологический сборник. – М., 1972. – С.62–68.

Насилов Д.М. К характеристике языковой ситуации в уйгурском государстве в IX–XIII вв. / Д.М. Насилов // Вестник шелкового пути. Вопросы тюркской филологии. Вт. II, Центр «Щелковый путь», 1993. – С. 60–77.

Насилов В. М. Язык тюркских памятников уйгурского письма XI–XV вв. / В. М. Насилов. – М.: Наука, 1974. – 101 с.

Нәҗип Ә.Н. Татар әдәбиятының һәм әдәби теленең кайбер онытылган язма истәлекләре турында / Ә.Н. Нәҗип // Совет әдәбияты. – 1957. – № 12. – С. 77–88.

Негматуллов М.М. Роль и место огузских элементов в истории развития татарского языка: дис. . . . канд. филол. наук / М.М. Негматуллов. – Казань, 1983. – 223 с.

Негматуллов М.М. Огузский пласт в татарском языке / М.М. Негматулов // Төркиләрнең телләре, рухи мәдәниятләре һәм тарихлары: традицияләр һәм заман. 1 том. – Казан, 1992. – Б. 146–149.

Нигматов Х.Г. Морфология языка восточно-тюркских памятников XI–XII вв.: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Баку, 1978.

Нигматуллов М.М. О некоторых огузских чертах в фонетике и грамматике татарских диалектов / М.М. Нигматуллов // Структура и история татарского языка. – Казань, 1982. – С. 73–79.

Нигматуллов М.М. Огузские элементы в татарском языке / М.М. Нигматуллов // Формирование татарского литературного языка. – Казань, 1989. – С. 96–100.

Нугайбәк Г. Төрлек. – Казань: Тип. И.Н. Харитонова, 1911. – 80 б.

Нуриева Ф.Ш. Отражение фонетических изменений в письменном памятнике XIV в. «Нахдж ал-Фарадис» / Ф.Ш. Нуриева // Вопросы истории диалектологии и функционирования языка. – Казань, 1998. – С. 126–135.

Нуриева Ф.Ш. Коллекция списков рукописи XIII–XIV вв. в рукописных хранилищах г. Казани, / Ф.Ш. Нуриева // Ученые записки. – Казань: Изд-во ТГГИ, 1999. – С. 133–148.

Нуриева Ф.Ш. «Нахдж ал-Фарадис» Махмуда ал-Булгари / Ф.Ш. Нуриева. – Казань: Фән, 1999. – 189 с.

Нуриева Ф.Ш. Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода / Ф.Ш. Нуриева. – Казань: Казан. гос. ун-т, 2004. – 376 с.

Нуриева Ф.Ш. Норма и вариативность в языке тюркоязычных памятников XIII–XIV веков Поволжья / Ф.Ш. Нуриева // Татар теле, әдәбияты, тарихы – үткәне, бүгенгесе. – Казань: Изд-во ТГГИ, 2000. – С. 207–213.

Нуриева Ф.Ш. Мәхмүт Болгари «Нәһҗел Фәрадис» (текстны хәзерге татар әдәби теленә күчерүче Ф.Ш. Нуриева) / Ф.Ш. Нуриева. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 358 б.

Нуриева Ф.Ш. Общий взгляд на развитие письменно-литературного старотатарского литературного языка (XIII–XIV вв.) / Ф.Ш. Нуриева // Языковые уровни и их анализ. – Казань: Изд-во ТГГИ, 2001. – С. 29–35.

Нуриева Ф.Ш. Основные звуковые процессы в языке тюрко-язычных письменных памятников XIV в. Поволжья / Ф.Ш. Нуриева // Материалы итоговой научно-практической конференции ТГГИ за 2000 год. – Казань: Изд-во ТГГИ, 2001. – С. 43–45.

Нуриева Ф.Ш. О роли поэта в произведении Хорезми «Мухаббат-наме» / Ф.Ш. Нуриева // Фәнни язмалар. – Казань: Школа, 2002. – С. 69–75.

Нуриева Ф.Ш. «Мухаббат-наме» Хорезми / Ф.Ш. Нуриева // История татарского литературного языка. – Казань: Фикер, 2003. – С. 220–239.

Нуриева Ф.Ш. Изучение истории тюркских литературных языков //Культура народов Причерноморья. – Киев, 2009. – № 158. – С. 123–127.

Нуриева Ф.Ш. Атрибуция языка письменных памятников золотоордынского периода / Ф.Ш.Нуриева. – Астана: Сарыарка, 2011. – 208 с.

Нуриева Ф.Ш. Язык письменных памятников золотоордынского периода / Ф.Ш. Нуриева // Туркі өркениеті жене тәуелсіз Қазақстан. Қазақстан Республикасы тәуелсіздігінің 20 жылдығына арналған халықаралық конференция материалдары. II (К–Ю) / Ш. Ибраевтың редакциясымын. – Астана, 2011. – Б. 229–236.

Нуриева Ф.Ш. О смешанности языка тюркских письменных источников золотоордынского периода // Средневековые тюрко-татарские государства. – 2014. – № 6. – С. 176–180.

Нуруллина Р. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985) / Р. Нуруллина. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1989.

Пылев А.И. Ходжа Ахмад Йасави – первый тюркский суфийский поэт Средней Азии: автореф. дис. ... канд. филол. наук / А.И. Пылев; СПб. гос. ун-т. – СПб., 2001. – 26 с.

Радлов В. Ярлыки Токтамыша и Тимиркутлуга / В. Радлов // Записки восточного отделения Императорского русского археологического общества. – СПб., 1889. – С. 1–40.

Ракушин А.И. Мусульманство у золотоордынских кочевников Нижнего Поволжья XIII–XV вв.: автореф. дис. ... канд. ист. наук / А.И. Ракушин. – Саратов, 1998. – 17 с.

Рамазанова Д.Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии / Д.Б. Рамазанова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 191 с.

Рамазанова Д.Б. К истории формирования говора пермских татар / Д.Б. Рамазанова. – Казань, 1996. – 240 с.

Расовский Д.А. К вопросу о происхождении Codex Cumanicus / Д.А. Расовский // Seminarium Kondakovianum. – 1929. – С. 211.

Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд. Борынгы дәвер. Икенче бүлек / Г. Рәхим, Г. Газиз. – Казан, 1924. – 175 б.

Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Икенче басма / Г. Рәхим, Г. Газиз. – Казан, 1925. – 316 б.

Рясянен М. Материалы по истории фонетики тюркских языков / М. Рясянен. – М.: Изд-во иностр. лит., 1955. – 222 с.

Садретдинов Ш., Гайнетдинов М. XIX гасырның беренче яртысында татар поэзиясе: Әбелмәних Каргалый (студентлар өчен ярдәмлек) / Ш. Садретдинов, М. Гайнетдинов. – Казан: Казан ун-ты нәшр. 1978. – 35 б.

Самойлович А.Н. Среднеазиатско-турецкие надписи на глиняном кувшине из Сарайчика / А.Н. Самойлович // ЗВОРАО, 1913, Т. XIX, вып. 1.

Самойлович А.Н. К истории литературного среднеазиатско-турецкого языка / А.Н. Самойлович // Мир Али Шир. – Л.,1928. – С. 3–25.

Сараи Сәйф. Гөлестан. Лирика. Дастан / С. Сараи. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 296 б.

Саттаров Г.Ф. Татарстан АССРның антропотопонимнары / Г.Ф. Саттаров. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1973. – 305 б.

Сәгъди Г. Әдәбият тарихымы, язмалар тарихымы / Г. Сәгъди // Безнең юл. – 1924. – № 13. – Б. 40–44.

Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы / Г. Сәгъди. – Казан: Татгосиздат. 1926. – 300 б.

Серебрянников Б.А. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков / Б.А. Серебрянников, Н.З. Гаджиева. – Баку: Маариф, 1979. – 304 с.

Серебренников Б.А. Об основных отличиях истории строевых элементов языка от истории литературного языка / Б.А. Серебренников // Советская тюркология. – Баку, 1981. – № 4. – С. 3–13.

Серебренников Б.А., Гаджиева Н.З. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. 2-е изд. , испр. и доп. / Б.А. Серебренников, Н.З. Гаджиева. – М. : Наука, 1986. – 301 с.

Соссюр Ф. Курс общей лингвистики / Фердинад де Соссюр // Труды по языкознанию. Перевод с французского А.М. Сухотина, переработаный А.А. Холодовичем. – М.: Прогресс, 1972. – 625 с.

Современный татарский литературный язык: Лексикология, фонетика, морфология. – М.: Наука, 1969. – 380 с.

Социальная и функциональная стратификация литературных языков. – М.: Наука, 1977. – 343 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Морфология. – М.: Наука, 1988. – 557 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Региональные реконструкции. – М.: Наука, 2002. – 767 с.

Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). – Казань: Фән, 1999. – 240

Старотатарская деловая письменнось XVIII века / сост. Ф.С. Фасеев. – Казань, 1982. – 171 с.

Тагирджанов А.Т. «Хосров и Ширин» Кутба: дис. ... канд. филол. наук / А.Т. Тагирджанов. – Ташкент, 1946. – 252 с.

Татар әдәбияты тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – I т. – 567 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – I том. Борынгы чор һәм урта гасырлар. – 415 б.

Татар грамматикасы: өч томда. – М.: Инсан; Казан: Фикер, 1998. – I т. – 512 б.; 1999. – III т. – 512 б.; 2002. – II т. – 448 б.

Татар мәгърифәтчелек әдәбияты (1860–1905). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 415 б.

Татарская грамматика: в 3-х т. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. – I т.: Происхождение языка. Фонетика. Словообразование. – 583 с.

Татарская грамматика: в 3-х т. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. – II т. Морфология. – 397 с.

Татар грамматикасы: өч томда. – Казан: Фикер; Мәскәү: Инсан, 2002. – II т: Морфология. – 448 б.

Татар теленең диалектологик сүзлеге. – Казан, 1969. – 644 б.

Таһирҗанов Г.Т. Тарихтан – әдәбиятка / Г.Т. Таһирҗанов. – Казан, 1979. – 167 б.

Тенишев Э.Р. К понятию общетюркское состояние / Э.Р. Тенишев // Советская тюркология. – 1971. – № 2. – С. 13–16.

Тенишев Э.Р. О построении народно-разговорного и литературного языков / Э.Р. Тенишев // Тюркологические исследования. – М., 1976. – С. 230–232.

Тенишев Э.Р. О наддиалектном характере языка тюркских рунических памятников / Э.Р. Тенишев // Tircologica. – Л., 1976. – С. 164–172.

Тенишев Э.Р. Функционально-стилистическая характеристика древнеуйгурского литературного языка / Э.Р. Тенишев // Социальная и функциональная стратификация литературного языка. – М., 1977. – 343 с.

Тенишев Э.Р. О методах и источниках сравнительно-исторических исследований тюркских языков / Э.Р. Тенишев // Советская тюркология. – 1977. – № 5. – С. 119–124.

Тенишев Э.Р. Языки древне- и среднетюркских письменных памятников в функциональном аспекте / Э.Р. Тенишев // Вопросы языкознания. – 1979. – № 2.– С. 85–93.

Тенишев Э.Р. Новый список Рабгузи / Э.Р. Тенишев // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983. – С. 25–31.

Тенишев Э.Р. Принципы составления исторических грамматик и истории литературных языков / Э.Р. Тенишев // Советская тюркология. – 1988. – № 1. – С. 67–78.

Тумашева Д.Г. Көнбатыш Себер татарлары теле. Грамматик очерк һәм сүзлек / Д.Г. Тумашева. – Казан: КДУ нәшр. , 1961. – 233 б.

Тумашева Д.Г. Язык сибирских татар / Д.Г. Тумашева. – Казань: Изд-во КГУ, 1977. – 294 с.

Тумашева Д.Г. Об особенностях развития старотатарской деловой письменности / Д.Г. Тумашева, М. А. Усманов, Ф. М. Хисамова // Советская тюркология. – Казань, 1977. – № 3. – С. 51–66.

Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология. – Казан: Казан ун-ты нәшр. , 1978. – 221 б.

Тумашева Д.Г. Татар морфологиясен өйрәнү һәм кайбер теоретик мәсьәләләр / Д.Г. Тумашева // Очерки по морфологии татарского глагола. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1978. – Б. 5–26.

Тумашева Д.Г. Татарский глагол / Д.Г. Тумашева. – Казань: Изд-во Казан ун-та, 1986. – 189 с.

Тумашева Д.Г. Старотатарская деловая письменность и историческая диалектология / Д.Г. Тумашева, Ф.М. Хисамова // Проблемы диалектологии и лингвогеографии тюркских языков. – Уфа, 1986. – 165 с.

Усманов М.А. Татарские исторические источники XVI–XVIII вв. / М.А. Усманов. – Казань: Изд-во Казан ун-та, 1972. – 318 с.

Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. / М.А. Усманов. – Казань: Изд-во Казан ун-та, 1979. – 318 с.

Усманов М.А. Этапы исламизации Джучиева Улуса и мусульманского духовенства в татарских ханствах XIII–XVI вв. / М.А. Усманов, // Духовенство и политическая жизнь на Ближнем и Среднем Востоке в период феодализма. – М., 1985. – С. 177–185.

Фазылов Э.И. Староузбекский язык. Хорезмские памятники XIV в. / Э.И. Фазылов. – Ташкент: Фэн, 1966. – Т. I. – 650 с; – 1971. – Т. II. – 779 с.

Фасеев Ф.С. Краткий грамматический справочник татарского языка / Ф.С. Фасеев // Татарско-русский словарь. – М.: Сов. энциклопедия, 1966. – С. 807–867.

Фасеев Ф.С. Старотатарская деловая письменность XVIII в / Ф.С. Фасеев. – Казань, 1982. – 168 с.

Фахрутдинов Р.Г. История татарского народа и Татарстана / Р.Г. Фахрутдинов. – Казань: Магариф, 1995. – 255 с.

Фәхрутдинов Ф. Болгар шәһәрләре / Ф. Фахрутдинов // Казан утлары. – 1970. – № 2. – Б. 167–179.

Фәтхи А. Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. 3 бүлектән / А. Фәтхи. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1968. – 84 б.

Формирование татарского литературного языка. – Казань: ИЯЛИ, 1989. – 120 с.

Хайрутдинова Т.Х. Говор златоустовских татар / Т.Х. Хайрутдинова. – Казан: Татар. кн. изд-во, 1985. – 157 с.

Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар / Ф.С. Хакимзянов. – М.: Наука, 1978. – 206 с.

Хакимзянов Ф.С. О поволжском варианте среднетюркского литературного языка / Ф.С. Хакимзянов // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983. – С. 9.

Хакимзянов Ф.С. О языке межэтнического общения в Волжской Булгарии / Ф.С. Хакимзянов // К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. – Казань, 1985. – С. 90.

Хакимзянов Ф.С. Варианты реализации поволжского литературного языка // Старотатарский литературный язык: исследования и тексты. – Казань, 1991. – С. 28–36.

Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар / Ф.С. Хакимзянов. – М.: Наука, 1978. – 207 с.

Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники волжских булгар и их язык / Ф.С. Хакимзянов. – М.: Наука, 1987. – 101 с.

Хакимзянов Ф.С. Булгарский литературный язык или же Литературный язык булгарской эпохи? / Ф.С. Хакимзянов // Тенишевские чтения – 2008: сб. научных статей. – Казань: ТГГПУ. – 256 с.

Хаков В.Х. Развитие татарского литературного языка и его стилей: автореф. дис. ... д-ра филол. наук / В.Х. Хаков. – Алма-Ата, 1971. – 60 с.

Хаков В.Х. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше / В.Х. Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр. , 1972. – 221 б.

Хаков В.Х. «Мәхәббәтнамә» әсәре һәм татар әдәбиятында аның традицияләре / В.Х. Хаков // Казан утлары, 1980. – № 3. – Б. 161–167.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы һәм этнолингвистика / В.Х. Хаков // Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка. – Казан, 1992. – Б. 25–32.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы / В.Х. Хаков. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 323 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теленең совет чорында үсеше / В.Х. Хаков. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1985. – 150 б.

Хаков В.Х. «Рисалэ-и Таварихе Булгария» Хисамт-дина бин Шарафут-дина эль-Булгари / В.Х. Хаков // Анализы текстов по истории татарского литературного языка. – Казань, 1987. – Б. 113–120.

Хаков В.Х. Казан ханлыгы чорында әдәби тел // Мирас. – 1993. – № 8. – Б. 132–140.

Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе / Вахит Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

Халиков А.Х. Татарский народ и его предки / А.Х. Халиков. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – 222 с.

Халиуллина А.Р. Графо-фонетические и морфологические особенности тюркоязычного письменного памятника XIV в. «Кысас-ал Анбия» Насретдина Рабгузи: дис. ... канд. филол. наук / А.Р. Халиуллина. – Казань, 2002. – 229 с.

Хангильдин В.Н. Татар теле грамматикасы (морфология буенча очерклар) / В.Н. Хангильдин. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 335 б.

Хәзерге татар әдәби теле: (Лексика. Фонетика. Орфоэпия. Графика һәм орфография). Югары уку йорты студентлары һәм урта мәктәп укытучылар өчен. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. – 299 б.

Хәзерге татар әдәби теле. Югары уку йортлары студентлары өчен программаның тулыландырылган һәм төзәтелгән дүртенче басма. – Казан, 2002. – 51 б.

Хидиятов И.Р. Язык письменных памятников периода Казанского ханства (XVI в.) и татарские говоры в сравнительном аспекте: морфология: автореф. ... канд. филол.наук / И.Р. Хидиятов. – Казань, 2005. – 21 с.

Хисамиева З.А. Язык дастанов Кадыр-Гали Бека: автореф. дис... канд. филол. наук / З.А. Хисамиева. – Уфа, 1980. – 20 с.

Хисамиева З.А. Язык дастанов Кадыр-Гали бека: дис. ... канд. филол. наук / З.А. Хисамиева. – Уфа, 1980. – 231 с.

Хисамов Н.Ш. Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али / Н.Ш. Хисамов. – М.: Наука, 1979. – 251 с.

Хисамов Н. Яңача фикерләү һәм урта гасыр әдәбиятын өйрәнүнең принципиаль мәсъәләләре / Н. Хисамов // Казан утлары. –1997. – № 3. – Б. 183.

Хисамов Н. XIX йөз шигъриятендә кеше идеалы / Н. Хисамов // Казан утлары. – 1997. – № 3. – Б. 157–171.

Хисамова Ф.М. Туган тел һәм милләт язмышы // Татарика. – № 1. – 2013. – Б. 23–35.

Хисамова Ф.М. XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре / Ф.М. Хисамова. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981. – 162 б.

Хисамова Ф.М. XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре / Ф.М. Хисамова. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981. – 161 б.

Хисамова Ф.М. Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI–XVII вв. / Ф.М. Хисамова. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. – 151 с.

Хисамова Ф.М. Язык деловой письменности и его место в функциональной парадигме татарского языка XVII–XVIII веков / Ф.М. Хисамова // Старотатарский литературный язык: исследование и тексты. – Казань, 1991. – С. 60–80.

Хисамова Ф.М. Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности (XVI – нач. XVII в.): дис. ... д-ра филол. наук / Ф.М. Хисамова; Казан. гос. ун-т. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1995. – 418 с.

Хисамова Ф.М. Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX в. ) / Ф.М. Хисамова. – Казань, 1999. – 408 с.

Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен дәреслек / Ф.М. Хисамова. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.

Хисматуллин Х. Мәүла Колый иҗаты. 1963.

Хөснетдинов Р.М. «Шура» журналында язма әдәби тел мәсьәләләре (1908–1917): монография / Р.М. Хөснетдинов. – Казан: КМТТУ нәшрияты, 2015. – 164 б.

Хусаинов Г.Б. Новонайденные рукописные хикметы Мавля Кулуя // Письменные памятники Башкирии (историко-филологические исследования). – Уфа, 1982. – С. 152–163.

Чеченов А.А. Язык памятника XIV века Codex Cumanicus в ареальном освещении / А.А. Чеченов. – М.: Наука, 1978. – 186 с.

Шамарова Г.Б. Язык дастанов А. Уразаева Курмаши «Кисса-и – Бүз Джигит», «Кисса-и Тахир и Зухра» (истоки и традиции): автореф. дис. ... канд. филол. наук / Г.Б. Шамарова. – Казань, 1991. – 24 с.

Шарипов А.М. Зарождение и становление системы стихотворных жанров в древнетюркской и тюрко-татарской литературе (VIII–XIV вв.) / А.М. Шарипов. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2001. – 364 с.

Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской гу бер нии / С.М. Шпилевский. – Казань, 1877.

Щербак А.М. Огуз-наме. Мухаббат-наме. Памятники древнеуйгурской и староузбекской письменности / А.М. Щербак. – М., 1959. – 270 с.

Щербак А.М. Грамматический очерк языка тюркских текстов X–XIII веков из восточного Туркестана / А.М. Щербак. – М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1961. – 204 с.

Щербак А.М. Грамматика староузбекского языка / А.М. Шербак. – М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1962. – 274 с.

Щербак А.М. Сравнительная фонетика тюркских языков / А.М. Щербак. – Л.: Наука, 1970. – 204 с.

Щербак А.М. Формы желательного наклонения в тюркских языках / А.М. Щербак // TURCOLOGICA. – М., 1976. – С. 17–23.

Щербак А.М. Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков (глагол) / А.М. Щербак. – Л.: Наука, 1981. – 183 с.

Юзмухаметов Р.Т. Структура текста и язык книги «Мустафад аль-ахбар фи ахвали Казан ва Булгар» Шигабутдина Марджани: учебно-методическое пособие / Р.Т. Юзмухаметов. – Казань: Казан. гос. ун-т, 2003. – 180 с.

Юлдашев А.А. Аналитические формы глагола в тюркских языках / А.А. Юлдашев. – М.: Наука, 1965. – 275 с.

Юсупов А.Ф. Язык произведений Шамсетдина Заки. Морфология / А.Ф. Юсупов. – Казань: Казан. гос. ун-т, 2006. – 204 с.

Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику / Г.В. Юсупов. – М. – Л., 1960. – С. 183–185.

Юсупов Ф.Ю. Неличные формы глагола в диалектах татарского языка / Ф.Ю. Юсупов. – Казань: Изд-во азан. ун-та, 1985. – 318 с.

Юсупов Ф.Ю. Изучение татарского глагола / Ф.Ю. Юсупов // Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 287 с.

Юсупов Ф.Ю. Морфология татарского диалектного языка: категории глагола / Ф.Ю. Юсупов. – Казань: Фэн, 2004. – 592 с.

Язык письменных памятников золотоордынского периода // Золотая Орда в мировой истории. The Golden Horde in World Historiy / Коллективная монография. Институт истории им. Марджани, Оксфордский университет. – Казань, 2016. – С. 502–515.

Языки мира: Тюркские языки. – Бишкек: Кыргызстан, 1997. – 543 с.

Ярцева В.Н. История английского литературного языка IX–XV вв. / В.Н. Ярцева. – М.: Наука, 1985. – 247 с.

Яфаров Б.А. X–XIV йөзләрдә Кама-Волга болгарлары әдәбияты һәм «Нәһҗ әл-фәрәдис» кулъязмасы: филол. фән. канд. ... дис. / Б.А. Яфаров. – Казан, 1949. – Б. 62–150.

Яхин Ф. Татарская литература периодической печати Уральска (1905–1907) / Ф. Яхин. – Казань: Татар. кит. нәшр., 1992. – 125 с.

XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. – Казан: Дом печати, 2006. – 363 б.

XVIII гасыр татар әдәбияты. Проза. – Казан: Дом печати, 2006. – 363 б.

Aysu Ata. Harezm-Altın Ordu Türkçesi. – Ankara: Ankara Universitesi Basımevi. – 2014. – 186 s.

Aysu Ata. Kısasül Enbıya. I. Giriş Metin Tıpkıbasım. – Ankara. 1997. – 616 с.

Eckmann J. Nehcü'l-Faradis'in Bilinmeyen bir Xazmati / J. Eckmann // Turk Dili Aras trmalari Yilligi Belleten. – Ankara, 1964. – S. 157–159.

Eckmann J. Die Kiptschakische Literatur von Janos Eckmann / J. Eckmann // Filologiae Turcicae Fundamenta. – Wiesbaden, 1964. – S. 280–285.

Clauson G. An etimological Dictionary of prethirteenth cen Aury Turkish / G. Clauson. – Oxford, 1972. – S. 74–166.

Hacieminoğlu N. Kutb'un Husrev Şirin'i ve Dil Hususiyetleri / N.Hacieminoğlu. – Ankara: Tükr Dil Kurumu, 2000. – 478 s.

Karamanlioglu A.F. Seyfi Sarayi. Gülistan Tercümesi / A.F. Karamanlioglu. – Ankara, 1989. – 408 s.

Kivametdin Burslan Nehcül-Faradis'ten Derlenen Türkce sözler // Tűrkijat Mecmuasi ШМ. – Istambul, 1934. – S. 169–250.

Köprülü Fuad Türk Edebiyati Tatihi / F. Köprülü. – Istambul, 1926. – S. 344–347.

Mahmud b Kēdî Manyâs. Gulistan Tercümesi. Giris-inceleme-metin. Sözlük Hazirlayan Dx. Dr Mustafa Özkan. – Ankara, 1993. – 480 s.

Nurieva, F.Golden horde: written monuments' language

Özyetgin M.A. Altin ordu, kirim ve kazan sanasina ait varlik vebitik Lerin dil ve üslup incele mesi / A.M. Özyetgin. – Ankara. 1996. – 296 s.

Özyetgin M.A. Astrahanli Serifi nin 1550 tarihli zafer-namesi / A.M.Özyetgin. Türkoloji Dergisi, C. XI, S. 1,12 Ankara, 321–413.

Velidi Z. Harezmda yazilmis Eski Turkce Eserler / Z. Velidi // Turkiyat Mecmuasi ll, 1926/ Z.Velidi . – Istanbil, 1928. – S. 331–345.

بقرعان كتابى (БК). – Казань, 1894. – 80 с.

قصهء حبى خواجه (КХХ). – Казань: Типо-литография Императорского университета, 1899. – 16 с.

## ЭЧТӘЛЕК


**Кереш сүз** . . . . . 5
**Кереш** . . . . . 8
**1. Болгар дәүләте чоры Идел буе төрки язма әдәби теленең морфологик үзенчәлекләре** . . . . . 42
1.1. Исем . . . . . 45
1.2. Сыйфат . . . . . 61
1.3. Рәвеш . . . . . 69
1.4. Сан . . . . . 72
1.5. Алмашлык . . . . . 77
1.6. Фигыль . . . . . 87
1.6.1. Затланышлы фигыль формалары . . . . . 88
1.6.2. Затланышсыз фигыль формалары . . . . . 105
**2. Алтын Урда чоры Идел буе төрки-татар язма әдәби теленең морфологик үзенчәлекләре** . . . . . 112
2.1. Исем . . . . . 114
2.2. Сыйфат . . . . . 132
2.3. Рәвеш . . . . . 142
2.4. Сан . . . . . 145
2.5. Алмашлык . . . . . 153
2.6. Фигыль . . . . . 159
2.6.1. Затланышлы фигыль формалары . . . . . 160
2.6.2. Затланышсыз фигыльләр . . . . . 179
**3. Казан ханлыгы чоры иске татар язма әдәби теленең морфологик үзенчәлекләре** . . . . . 195
3.1. Исем . . . . . 196
3.2. Сыйфат . . . . . 208
3.3. Рәвеш . . . . . 211
3.4. Сан . . . . . 213
3.5. Алмашлык . . . . . 218
3.6. Фигыль . . . . . 227
3.6.1. Затланышлы фигыль формалары . . . . . 227
3.6.2. Затланышсыз фигыль формалары . . . . . 238

**4. XVII–XVIII гасырларда иске татар язма әдәби теленең морфологик үзенчәлекләре** . . . 249
4.1. Исем . . . 249
4.2. Сыйфат . . . 259
4.3. Рәвеш . . . 261
4.4. Сан . . . 263
4.5. Алмашлык . . . 264
4.6. Фигыль . . . 267
4.6.1. Затланышлы фигыль формалары . . . 267
4.6.2. Затланышсыз фигыль формалары . . . 280
**5. XIX гасыр – XX гасыр башында иске татар язма әдәби теленең морфологик үзенчәлекләре** . . . 291
5.1. Исем . . . 291
5.2. Сыйфат . . . 394
5.3. Рәвеш . . . 424
5.4. Сан . . . 438
5.5. Алмашлык . . . 458
5.6. Фигыль . . . 484
5.6.1. Затланышлы фигыль формалары . . . 492
5.6.2. Затланышсыз фигыль формалары . . . 706
Йомгак . . . 828
Әдәбият . . . 844

Научное издание

**ИСТОРИЯ ТАТАРСКОГО ЛИТЕРАТУРНОГО ЯЗЫКА**
**(XIII – начало XX века)**
II том
Морфология. Структурно-субстанциональные особенности
и функционально-стилистические возможности
грамматических категорий:
письменные традиции, норма и вариативность

На татарском языке

Редактор – Я.М. Абдулкадырова
Компьютерная верстка и дизайн обложки
Л.Ш. Давлетшиной

Подписано в печать: 23.12.2017.
Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 51,6. Уч.-изд. л. 49,8. Тираж 1000. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12